АКАДЕМИЯ НАУК СССР
КАЗАНСКИЙ ФИЛИАЛ
ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСТОРИИ

# РУССКО-ТАТАРСКИЙ СЛОВАРЬ

ТОМ
3

## П-Р

ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
РЕДАКЦИЯ НАУЧНО-ТЕХНИЧЕСКОЙ ЛИТЕРАТУРЫ
Казань 1958

СССР ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
КАЗАН ФИЛИАЛЫ
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ТАРИХ ИНСТИТУТЫ

# РУСЧА-ТАТАРЧА СҮЗЛЕК

ТОМ
3

П–Р

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
ФӘННИ-ТЕХНИК ӘДӘБИЯТ РЕДАКЦИЯСЕ
Казан 1958

СЛОВАРЬ СОСТАВИЛИ:

*Р. Ф. Шакирова* — (буква П от начала до слова „показывать").
*Э. М. Ахунзянов* — (буква П от слова „показывать" до слова „приз").
*Л. Т. Махмутова* — (буква П от слова „приз" до конца).
*Ф. С. Фасиев* — (буква Р полностью).

При составлении статей словаря на букву Р была использована часть картотеки, представленной *Ф. М. Газизовой*.

Редакционная коллегия:

*Р. С. Газизов, М. Максуд, К. С. Сабиров.*

Сүзлекне төзеделәр:

*Р. Ф. Шакирова* — (П хәрефенең баштан „показывать" сүзенә кадәр булган өлеше).
*Ә. М. Ахунҗанов* — (П хәрефенең „показывать" сүзеннән „приз" сүзенә кадәр булган өлеше).
*Л. Т. Мәхмутова* — (П хәрефенең „приз" сүзеннән ахырына кадәр).
*Ф. С. Фасиев* — (Р хәрефе).

Р хәрефен төзегәндә *Ф. М. Газизова* тарафыннан хәзерләнгән картотеканың бер өлешеннән файдаланылды.

Редакцион коллегия:

*Р. С. Газизов, М. Максуд, К. С. Сабиров*

## ОТ СОСТАВИТЕЛЕЙ

При составлении словаря основное внимание было обращено на более точную передачу значений русских слов на татарский язык. При этом особо серьёзное внимание уделялось тому, чтобы грамматическое оформление татарских слов, приводимых в качестве эквивалентов к русским словам, давало бы возможность употреблять их в связной речи в любом предложении.

Наибольшую трудность в этом отношении представляет передача на татарский язык русских относительных и притяжательных прилагательных, так как они могут быть переведены различными способами.

Во-первых, при помощи специальных суффиксов *-лы, -ле, -лык, -лек, -гы, -ге* и др., которые в татарском языке являются формальным показателем относительности имён прилагательных. Например, *летний* — җәйге; *летнее платье* — җәйге күлмәк; *солнечный* — кояшлы; *солнечный день* — кояшлы көн. Во-вторых, в тех случаях, когда русские относительные и притяжательные прилагательные в татарском языке не могут быть выражены каким-нибудь формальным показателем, их значение передаётся исходной формой имени существительного, которое, находясь в определённом контексте, может выполнять функцию относительного прилагательного. Например, выражение *каменный дом* на татарский язык может быть переведено как *таш өй*, где слово *таш* соответствует русскому слову *каменный*, а слово *өй* соответствует слову *дом*.

Таким образом, здесь русскому отымённому прилагательному *каменный* в татарском языке соответствует исходная форма имени существительного *таш*, употреблённая в функции прилагательного.

В настоящем словаре, как и в некоторых других русско-тюркских словарях, после таких прилагательных ставится многоточие. Оно показывает, что дальше следует определяемое им существительное. Например, *каменный* — таш...; *каменный дом* — таш өй; *деревянный* — агач...; *деревянный дом* — агач өй; *стеклянный* — пыяла...; *стеклянный стакан* — пыяла стакан и т. д.

Если же определяемое существительное принимает аффикс принадлежности 3-го лица *-ы, -е, -сы, -се,* то после многоточия в целях экономии места ставится только один из этих четырех вариантов — вариант *-ы.* Например, *колыбельный* — бишек...-ы; *колыбельная песня* — бишек җыры; *производственный* — житештерү...-ы, эшләп чыгару...-ы; производство...-ы; *производственные отношения* —

житештерү мөнәсәбәтләре; *производственный процесс* — производство процессы.

Составители словаря при переводе русских отымённых прилагательных пользовались также и другими известными способами передачи их на татарский язык, например, посредством наречий на *-ча*, *-чә*, *-лата*, *-ләтә*, сочетанием имени существительного с послелогом „белән“, именем существительным в местном падеже и т. д.

В подобных случаях для того, чтобы показать, что дальше следует определяемое существительное, ставится также многоточие. Например, *денежный* — акчалата...; *денежная помощь* — акчалата ярдәм; *вещевой* — әйберләтә...; әйберләр белән...; *вещевое довольствие* — әйберләтә тәэмин итү, әйберләр белән тәэмин итү; *дружеский* — дусларча...; *дружеский привет* — дусларча сәлам; *лабазный* — лабазда...; *лабазная торговля* — лабазда сату итү и т. д.

Прилагательные типа *литературный*, *классовый*, *научный* передаются существующими в татарском языке формами әдәби, сыйнфый, гыйльми, фәнни и т. п. Например, *классовая борьба* — сыйнфый көрәш; *научная работа* — фәнни эш; *литературное произведение* — әдәби әсәр.

Заимствованные относительные прилагательные типа *актуальный*, *социалистический*, *объективный*, *революционный* в словаре переданы при помощи суффиксов *-аль*, *-ик*, *-ив*, *-ион* и т. д. Например, *актуальный* — актуаль; *социалистический* — социалистик; *объективный* — объектив; *революционный* — революцион и др.

## ТӨЗҮЧЕЛӘРДӘН

Сүзлекне төзегәндә рус сүзләренең мәгънәләрен татарча мөмкин кадәр тулы һәм дөрес итеп бирү төп максат итеп куелды. Аерым алганда, рус сүзләренә эквивалент итеп китерелә торган татар сүзләрен грамматик яктан теләсә нинди җөмләдә кулланырлык итеп формалаштыруга зур игътибар бирелде.

Рус телендә исемнәрдән ясалган нисби сыйфатларны татар әдәби телендә нинди формаларда бирү мәсьәләсе шактый зур кыенлыклар тудыра. Андый нисби сыйфатларны татар әдәби телендә төрлечә бирергә мөмкин. Беренчедән, аларның кайберләре татар телендә исемнәргә *-лы, -ле, -лык, -лек, -гы, -ге* һ. б. аффикслар кушып ясалган сыйфатлар белән бирелә; мәсәлән, ***летний*** — җәйге; ***летнее платье*** — җәйге күлмәк; ***солнечный день*** — кояшлы көн. Икенчедән, әгәр дә рус телендәге нисби сыйфат татар телендә бернинди дә формаль күрсәткеч яки кушымча белән бирелә алмаса, аның мәгънәләре татарча контекстта аергыч функциясен үти торган баш килештәге исем белән бирелә. Мәсәлән, русча ***каменный дом*** дигән сүз тезмәсе татарча ***таш өй*** дип тәрҗемә ителә. Бу очракта русча ***каменный*** сүзенә татарча ***таш*** сүзе, ***дом*** сүзенә ***өй*** сүзе туры килә. Димәк, рус телендәге ***каменный*** нисби сыйфатына татар телендә баш килеш формасында аергыч функциясен үтәүче ***таш*** дигән исем туры килә. Ләкин татар телендә баш килеш формасындагы исем җөмләдән тыш алынганда бервакытта да сыйфат функциясен үти алмый. Шуңа күрә аның аергыч функциясендә килүен һәм аннан соң шул сүз тарафыннан ачыклана торган аерылмыш килүен күрсәтү өчен сүзлектә, шул типтагы кайбер башка сүзлекләрдәгечә, күп нокта куелды; мәсәлән, ***каменный*** — таш...; ***каменный дом*** — таш өй; ***деревянный*** — агач...; ***деревянный дом*** — агач өй; ***стеклянный*** — пыяла...; ***стеклянный стакан*** — пыяла стакан һ. б.

Әгәр дә ачыкланып килә торган исемнәр *-ы, -е, -сы, -се* тартым кушымчаларын ала торган булсалар, урынга экономия ясауны күздә тотып, аларның барысын да күрсәтеп тормыйча, күп ноктадан соң 3 нче зат тартым кушымчасы -ы гына куелды; мәсәлән, ***колыбельный*** — бишек...-ы; ***колыбельная песня*** — бишек җыры; ***производственный*** — житештерү...*-ы*; эшләп чыгару...-ы; производство...-ы; ***производственные отношения*** — житештерү мөнәсәбәтләре; ***производственный процесс*** — производство процессы.

Сүзлектә рус телендәге кайбер нисби сыйфатлар татар теленә

хас булган башка чаралар белән дә, мәсәлән, *-ча, -чә, -лата, -ләтә* формаларындагы рәвеш, *белән* бәйлеге кушып алынган исем һәм урын-вакыт килеше формасындагы исем белән бирелделәр. Бу очракларда да ачыклана торган аерылмыш урынына күп нокта куелды. Мәсәлән, *вещевой* — әйберләтә..., әйберләр белән...; *вещевое довольствие* — әйберләтә тәэмин итү, әйберләр белән тәэмин итү; *дружеский* — дусларча...; *дружеский привет* — дусларча сәлам; *лабазный* — лабазда...; *лабазная торговля* — лабазда сату итү и. т. д.

Рус телендәге *литературный, классовый, научный* тибындагы нисби сыйфатлар татар телендә яшәп килгән әдәби, сыйнфый, гыйльми, фәнни һ. б. формалар белән бирелде; мәсәлән, *классовая борьба* — сыйнфый көрәш; *научная работа* — фәнни эш; *литературное произведение* — әдәби әсәр.

*Актуальный, социалистический, объективный, революционный* кебек алынма нисби сыйфатлар сүзлектә *-аль, -ив, -ик, -ион* һ. б. аффикслар белән бирелде, мәсәлән, *актуальный* — актуаль, *социалистический* — социалистик, *объективный* — объектив, *революционный* — революцион һ. б.

## ЗНАКИ ПРЕПИНАНИЯ

(тыныш билгеләре)

, (запятая) в переводной части отделяет татарские слова с одинаковыми или очень близкими значениями.

; (точка с запятой) отделяет татарские слова с более далёкими значениями, а также пример от данного значения слова.

. (точка) ставится после арабских цифр при перечислении различных значений русского слова, в конце абзаца, а также после каждого фразеологического оборота.

: (двоеточие) ставится после русского слова в тех случаях, когда слово употребляется только в словосочетаниях.

... (многоточие) заменяет пропущенное слово или недосказанную часть слова.

— (тире) ставится между русскими и татарскими словами, а также между примерами и их переводами.

...- (многоточие и дефис) ставится перед татарским аффиксом, который по своему значению соответствует русскому слову.

I, II, III ... — служат для различения омонимов.

1, 2, 3, ... — ставятся при перечислении значений русского слова.

а, б, в... — когда некоторые значения слова объединяются одним термином, толкования этих значений даются в скобках и отделяются друг от друга буквами.

◇ (ромб) ставится перед идиоматическими и фразеологическими оборотами. За знаком ромб иногда приводятся специфические случаи словоупотребления.

# УСЛОВНЫЕ СОКРАЩЕНИЯ

*ав.*— авиация
*агр.*— агрономия
*анат.*— анатомия
*апт.*— аптекарское
*археол.*— археология
*архит.*— архитектура
*астр.*— астрономия
*безл.*— безличная форма (затланышсыз форма)
*биол.*— биология
*биохим.*— биохимия
*бот.*— ботаника
*бран.*— бранное слово (эрләү сүзе)
*бухг.*— бухгалтерия
*ввод. сл.*— вводное слово (кереш сүз)
*вет.*— ветеринария
*вин.*— винительный падеж
*воен.*— военное (хәрби сүз)
*вульг.*— вульгарное слово
*геогр.*— география
*геодез.*— геодезия
*геол.*— геология
*гл.*— глагол (фигыль)
*горн.*— горное (тау эшендә кулланыла торган)
*грам.*— грамматика
*дат.*— дательный падеж
*детск.*— детское слово (балалар сүзе)
*дипл.*— дипломатия
*дореvол.*— дореволюционное (революциягә кадәр кулланылган сүз)
*др.*— другие (башкалар)
*ед.*— единственное число (берлек саны)
*ест.*— естествознание
*ж.*— женский род
*ж.-д.* — железнодорожное (тимер юл эшендә кулланыла торган сүз)
*живоп.*— живопись
*загр.*— за границей
*знач.*— значение
*зоол.*— зоология
*ирон.*— иронически (көлеп әйтелә торган)
*искус.*— искусство
*истор.*— историческое (тарихи сүз)
*к.*— кара (смотри)
*канц.*— канцелярское (канцелярия эшендә кулланыла торган)
*книж.*— книжное (китап сүзе)
*ком.*— коммерческое
*крат. ф-мы.*— краткой формы
*кулин.*— кулинария
*ласк.*— ласкательное (иркәләү сүзе)
*лингв.*— лингвистика
*лит.*— литературоведение
*м.*— мужской род
*мат.*— математика
*мед.*— медицина
*межд.*— междометие (ымлык)
*метеор.*— метеорология
*местоим.*— местоимение (алмашлык)
*мин.*— минералогия
*миф.*— мифология
*мн.*— множественное число (күплек саны)
*многокр.*— многократный вид (кабатлаулы күренеш)
*мор.*— морское дело (диңгез эшендә кулланыла торган)
*муз.*— музыка
*нареч.*— наречие (рәвеш)
*нар.-поэт.*— народное-поэтическое
*науч.*— научное (фәнни)
*неодобр.*— неодобрительно
*нескл.*— несклоняемое слово (төрләнми торган сүз)
*несов.*— несовершенный вид
*обл.*— областное (җирле сөйләштә кулланыла торган)
*однокр.*— однократный вид
*отриц.*— отрицание, отрицательный
*офиц.*— официальное (рәсми сүз)
*охот.*— охотничье (аучылык термины)
*п.*— падеж (килеш)
*перен.*— переносное значение (сүзнең күчмә мәгънәсе)
*плот.*— плотничье дело (балта осталыгы эше)
*повел. накл.*— повелительное наклонение (боерык фигыль)
*погов.*— поговорка (әйтем)
*полит.*— политика
*порт.*— портновское дело
*посл.*— пословица (мәкаль)
*поэт.*— поэтическое
*предл.*— предложный падеж
*презрит.*— презрительно
*пренебр.*— пренебрежительно (кимсетеп әйтү сүзе)
*прил.*— имя прилагательное (сыйфат)
*простореч.*— просторечие (халык телендә кулланыла торган)
*псих.*— психология
*публиц.*— публицистика
*радио.*— радиотехника
*разг.*— разговорное (сөйләшү телендә кулланыла торган)
*рел.*— религиозное (дини сүз)
*ритор.*— риторическое
*род.*— родительный падеж
*рыболов.*— рыболовное дело
*сад.*— садоводство
*сапож.*— сапожное дело
*сказ.*— сказуемое (хәбәр)
*собир.*— собирательное
*сов.*— совершенный вид
*социол.*— социология

*спец.*— специальное (махсус термин)
*спорт.*— спортивное (спорт термины)
*ср.*— средний род
*сравн. ст.*— сравнительная степень (чагыштыру дәрәҗәсе)
*старин.*— старинное
*столяр.*— столярное дело
*страд.*— страдательный залог (төшем юнәлеше)
*сущ.*— имя существительное (исем)
*с.-х.*— сельское хозяйство
*театр.*— театральное (театр һәм сәхнә өлкәсендә кулланыла торган)
*текст.*— текстильное (туку эшендә кулланыла торган)
*тех.*— техника
*тип.*— типографское дело (типография эшендә кулланыла торган)
*торг.*— торговое (сәүдә эшендә кулланыла торган)
*торж.*— торжественное
*увелич.*— увеличительное
*уменьш.*— уменьшительное
*уничижит.*— уничижительное
*устар.*— устарелое (искергән сүз)
*фам.*— фамильярное (игътибарсыз, илтифатсыз әйтелгән сүз)
*фарм.*— фармацевтическое
*физ.*— физика
*физиол.*— физиология
*филос.*— философия
*фин.*— финансы
*фольк.*— фольклор (халык иҗаты)
*фот.*— фотография
*хим.*— химия
*церк.*— церковное (чиркәү сүзе)
*ч.*— число (сан)
*шахм.*— шахматный термин (шахмат термины)
*школьн.*— школьное
*шутл.*— шутливое (шаяртып әйтелә торган сүз)
*эвф.*— эвфемистически
*эк.*— экономика
*эл.*— электричество
*этногр.*— этнография
*этнол.*— этнология
*юр.*— юридический термин
*һ. б.*— һәм башкалар
*һ. ш. о.*— һәм шуңа охшашлылар

## РУССКИЙ АЛФАВИТ

(рус алфавиты)

А Б В Г Д Е Ж З И Й К Л М Н
О П Р С Т У Ф Х Ц Ч Ш Щ
Ъ Ы Ь Э Ю Я

# П

**ПА** *ср. нескл.* — па (танецта аерым фигура — үзенә бер төрле аяк басышы белән эшләнә торган ритмик хәрәкәт; *вальс в три па* — өч палы вальс).

**ПА'ВА** *ж.* — ана тавис.

**ПАВИА'Н** *м.* — павиан (башы эт башына охшаган маймыл).

**ПА'ВИЙ** *устар.* — к. павлиний.

**ПАВИЛИ'КА** *ж.* — к. повилика.

**ПАВИЛЬО'Н** *м.* — павильон (1. бакчада, паркта була торган җиңел конструкцияле кечкенә бина, беседка; 2. сәүдә итү яки башка максатлар өчен төзелгән кечкенә генә корылма; мәсәлән, чәчәкләр павильоны, минераль сулар сату павильоны; 3. күргәзмәнең аерым бүлегенә караган экспонатларны урнаштыру өчен билгеләнгән бина; 4. киносъёмкалар, фотосъёмкалар өчен эшләнгән махсус бина).

**ПАВИЛЬО'ННЫЙ** — **1.** павильон...-ы; павильондагы; *павильонные работы* — павильон эшләре; павильондагы эшләр; **2.** павильонда башкарыла торган; *павильонные съёмки* — павильонда башкарыла торган съёмкалар.

**ПАВЛИ'Н** *м.* — тавис.

**ПАВЛИ'НИЙ** — тавис...-ы; *павлиний хвост* — тавис койрыгы. ◇ **Павлиний глаз** — тавис күзе (күбәләк). **Ворона в павлиньих перьях** — к. ворона.

**ПА'ВОДКОВЫЙ** *спец.* — **1.** ташу...-ы; *паводковые воды* — ташу сулары; **2.** ташу сулары белән...; *паводковое орошение* — ташу сулары белән сугару.

**ПА'ВОДОК** *м.* — ташу; ташкын, ташу суы; *весенний паводок* — язгы ташу.

**ПА'ВОЗКА** *ж.*, **ПА'ВОЗОК** *м. обл.* — зур көймә (сай елгаларда йөк ташу өчен кулланыла торган җилкәнле көймә).

**ПА'ВОЛОКА** *ж. старин.* — паволока (борынгы Русьта читтән кертелгән кыйммәтле тукыма).

**ПА'ВШИЙ** — һәлак булган, корбан булган (сугышта, көрәштә); *солдаты, павшие в боях за Родину* — Ватан өчен сугышларда һәлак булган солдатлар.

**ПАГАНИ'ЗМ** *м. мн.* нет — паганизм, мәҗүсилек, потка табыну, потка табынучылык.

**ПАГИНА'ЦИЯ** *ж. спец.* — пагинация (китап битләренең тәртип номерларын күрсәткән саннар).

**ПА'ГОДА** *ж.* — пагода (буддистлар гыйбадәтханәсе).

**ПА'ГОЛЕНОК** *м. обл.* и *спец.* — куныч, итек кунычы, оек куннчы.

**ПА'ГУБА** *ж. мн.* нет — һәлакәт, зыян, зарар; *в знач. сказ.* бик зарарлы; *постоянное недосыпание* — *пагуба для здоровья* — һәрвакыт йокы туймау (яки йокы калдыру) сәламәтлек өчен бик зарарлы.

**ПА'ГУБНОСТЬ** *ж. мн.* нет — һәлакәтлелек, зарарлылык.

**ПА'ГУБНЫЙ** — һәлакәтле, зарарлы, зыянлы, бәлале, һәлакәткә китерүчән; *пагубное влияние* — зарарлы тәэсир; *пагубные последствия* — зарарлы нәтиҗәләр.

**ПА'ДАЛИЦА** *ж. мн.* нет, *обл.* — **1.** коелдык, (башагыннан) коелган орлык; коелган җимеш; **2.** коелган орлыктан үсеп киткән башаклар.

**ПА'ДАЛЬ** *ж. мн.* нет — **1.** үләксә; **2.** *обл.* (агачтан) коелган җимешләр, коелдык.

**ПА'ДАНЕЦ** *м.* — (агачтан) коелган җимеш, коелдык.

**ПА'ДАНКА** *ж. обл.* — к. падалица.

**ПА'ДАТЬ** *несов.* — **1.** коелу; *листья падают с деревьев* — агачлардан яфраклар коела; **2.** егылу; егылып төшү; *падать с лошади* — аттан егылып төшү; **3.** ишелү, аву, җимерелү; *забор падает* — койма ава; *дом падает* — өй ишелә; **4.** төшү; *у меня зубы падают* — тешләрем төшә; *тень падает на землю* — җиргә күләгә төшә; *все заботы падают на меня одного* — барлык мәшәкатьләр бер минем өстемә төшә; *ударение падает на последний слог* — басым соңгы иҗеккә төшә; **5.** яву; *снег перестал падать* — кар явып туктады; **6.** каплау, төшү; *падает сизый туман на долину* — үзәнгә күксел томан төшә; **7.** төшеп тору; *её волосы падали на плечи* — аның чәчләре җилкәсенә төшеп тора(лар) иде; **8.** үлү, кырылу; *скот падает* — хайваннар үлә; **9.** (өлешкә) тию; *каждый кусок хлеба, падавший на мою долю, ложился камнем на душу мне (Горький)* — минем өлешкә тигән һәрбер икмәк телеме йөрәгемә авыр таш булып ята иде; **10.** кимү; *добыча угля не падает, а повышается с каждым годом* — күмер чыгару кимеми, ә ел саен арта бара; **11.** бетүгә йөз тоту, түбән төшү, бетүгә таба бару; *буржуазное искусство падает* — буржуаз сәнгать түбән төшә; **12.** бетә бару, кими бару; *влияние его падает* — аның йогынтысы бетә бара. ◇ **Падать духом** — рух төшү, төшенкелеккә бирелү. **Сердце**

падает *у кого-нибудь* — (кем дә булса) куркуга төшә, өметсезлеккә бирелә. **Падать в обморок** — һуш китү, һуш китеп егылу, һуштан язу.

**ПА'ДАЮЩАЯ БА'ШНЯ** — авыш ясалган (авышкы) манара; *падающая башня в городе Пизе* — Пиза шәһәрендәге авыш ясалган манара.

**ПА'ДАЮЩАЯ ЗВЕЗДА'** — атылган йолдыз (метеор).

**ПА'ДДУГА** *ж.* — к. падуга.

**ПА'ДЕВЫЙ: падевый мёд** — яфрак балы.

**ПАДЕ'Ж** *м. грам.* — килеш.

**ПАДЁЖ** *м.* — үләт, терлек кырылу, мур.

**ПАДЕ'ЖНЫЙ** *грам.* — килеш...-ы; *падежные окончания* — килеш кушымчалары.

**ПАДЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — 1. төшү; *закон падения тел* — җисемнәрнең төшү законы; *угол падения равен углу отражения (физ.)* — нурның төшү почмагы аның чагылу почмагына тигез була; *падение цен* — бәяләрнең төшүе; 2. кимү; *падение производства* — эшләп чыгаруның кимүе; *сильное падение воды в плотине* — буадагы суның нык кимүе; 3. егылып төшү; *падение с лошади* — аттан егылып төшү; 4. бәреп төшерелү, бирелү; *падение царского режима в феврале 1917 г.* — 1917 нче елның февралендә патша режимының бәреп төшерелүе; *падение вражеской крепости* — дошман крепостеның бирелүе (алынуы); 5. таркалу; *дошёл до полного морального падения* — мораль яктан тәмам таркалды.

**ПА'ДИНА** *ж. обл.* — к. падь.

**ПАДИША'Х** *м.* — патша, падишаһ.

**ПА'ДКИЙ** — комсыз, ябышып ятучан, ябырылучан, яратучан; *падок до сладкого* — татлыны яратучан.

**ПА'ДУБ** *м. бот.* — к. остролист.

**ПА'ДУГА** *ж. театр.* — падуга (сәхнәнең өске өлешендәге механизмны каплап тора торган ярдәмче декорация).

**ПАДУ'ЧАЯ: падучая болезнь** — бума авыруы, үз чире, зыяндаш авыруы, эпилепсия; **падучая звезда** *(устар.)* — к. падающая звезда.

**ПАДУ'ЧКА** *ж. мн.* нет, простореч. — к. падучая.

**ПА'ДЧЕРИЦА** *ж.* — үги кыз.

**ПА'ДШИЙ: падший человек** — мораль яктан түбән төшкән кеше; **падшая женщина** — фахишә, бозык хатын.

**ПАДЬ** *ж. обл.* — тирән чокыр, тарлавык.

**ПАЕВО'Й** — пай...-ы; *паевой взнос* — пай взносы; *паевая книжка* — пай кенәгәсе; *паевый капитал* — пай капиталы.

**ПАЁК** *м.* — паёк; *солдатский паёк* — солдат паёгы.

**ПАЕНАКОПЛЕ'НИЕ** *ср. экон.* — пай туплау; *усиление паенакопления* — пай туплауны көчәйтү.

**ПАЖ I** *м.* — паж (1. *истор.* урта йөзләрдә — таҗ ияләренә ясә зур дәрәҗәле кешеләргә, күбесенчә хатын-кызга, хезмәт итүче дворян малае; 2. *перен. разг. ирон. шутл.* берәр хатын-кыз артыннан бик бирелеп йөрүче яшь кеше; 3. *истор.* патша сараенда түбән дәрәҗәле хезмәт урыны; 4. патша Россиясендә — Пажеский корпуста тәрбияләнүче).

**ПАЖ II** *м. устар.* — паж (озын юбканы күтәртеп тора торган кыстыргычлы пояс).

**ПА'ЖЕСКИЙ: Пажеский корпус** *доревол.* — Пажеский корпус (дворян балалары өчен билгеләнгән хәрби уку йорты).

**ПА'ЖИТЬ** *ж. поэт.* и *обл.* — к. пастбище.

**ПАЗ** *м. спец.* — 1. ярык, җек; *законопатить пазы* — җекләрне мүкләү; 2. уем, ырмау, паз; *выбирать пазы* — ырмаулар уеп алу.

**ПА'ЗИТЬ** *несов. спец.* — уем ясау, ырмау алу, уеп алу (бүрәнәдә, агачта, тактада һ. б.).

**ПАЗНИ'К** *м. спец.* — пазник (паз алу өчен кулланыла торган струг).

**ПА'ЗУХА** — 1. *разг.* куен; *засунуть руку за пазуху* — кулны куенга тыгу; 2. *анат.* куышлык (тәндә); *лобные пазухи* — маңгай куышлыклары; *мышечные пазухи* — мускул куышлыклары. ◇ **Камень за пазухой держать** — кесәдә таш йөртү (үч тоту). **Как у Христа за пазухой (жить)** *разг. устар.* — тыныч яшәү, иркен яшәү.

**ПА'ЗУШИНА** *ж. архит.* — гөмбәз, көймә; *пазушина окна* — тәрәзә гөмбәзе.

**ПА'ИВАТЬ I** *несов. простореч.* — эчертү, эчергәләү.

**ПА'ИВАТЬ II** *несов. простореч.* — кургаш коеп ябыштыру, паять итү.

**ПА'ИНЬКА** *м.* и *ж. разг. фам.* — тыңлаучан бала, акыллы бала.

**ПАЙ I** *м.* — 1. пай (теге яки бу оешманың средствосына шул оешманың берәр члены тарафыннан кертелә торган өлеш); 2. өлеш. ◇ **На паях** *разг.* — акча салышып, пай кертеп. **Принять в пай** — пайга кертү.

**ПАЙ II** *нескл. м.* и *ж.* — тыңлаучан, акыллы; *пай мальчик* — тыңлаучан малай, акыллы малай.

**ПАЙКО'ВЫЙ** *разг.* — паёк итеп бирелгән, паёк итеп бирелә торган, паёк хисабына бирелгән; *пайковый сахар* — паёк итеп бирелгән шикәр.

**ПА'ЙЩИК I** *м.*, **ПА'ЙЩИЦА** *ж.* — пайчы, пай керткән кеше; *общее собрание пайщиков кооперативного товарищества* — кооператив ширкәте пайчыларының гомуми җыелышы.

**ПА'ЙЩИК II** *м. спец.* — паять итүче; *пайщик кабелей* — кабельләрне паять итүче.

**ПАК** *м. мн.* нет, *спец.* — пак (поляр диңгезләрдә судноларга йөрешен читенләштерә торган купьеллык калын боз).

**ПАКГА'УЗ** *м. спец.* — пакгауз (таможняда, тимер юл станцияләрендә һ. б. товарлар, йөкләр саклау склады).

**ПАКГА'УЗНЫЙ** *спец* — пакгауз...-ы; *пакгаузный сторож* — пакгауз каравылчысы.

**ПАКЕ'Т** *м.* — 1. төргәк; *завернуть книги в два пакета* — китапларны ике төргәк итеп бәйләү; 2. пакет (а. продуктлар салу өчен кечкенә кәгазь капчык; б. рәсми хат салынган конверт). ◇ **Индивидуальный**

пакет *воен.*— индивидуаль пакет (медицина ярдәме күрсәтелгәнгә кадәр яраны бәйләү өчен кулланыла торган бинт белән мамык төргәге).

ПАКЕТБО'Т *м. мор. устар.*— пакетбот (дингездә почта һәм пассажирлар йөртү пароходы).

ПА'КИ *устар.* и *шутл.*— тагы, янадан.

ПАККА'МЕРА *ж. тех.*— паккамера (язу кәгазе производствосында әзер продукцияне сортларга аеру һәм рулонга чорнау цехы).

ПА'КЛЕН *м. бот.*— кара чаган.

ПА'КЛИНА *ж. обл.*— бер тотам талкыш, бер тотам чүбек.

ПА'КЛИТЬ *несов. обл.*— талкыш (чүбек, пәжә) белән мүкләү.

ПА'КЛЯ *ж. мн.* нет — талкыш, чүбек.

ПАКОВА'ТЬ *несов.* — төреп бәйләү, тюкләү; *паковать книги* — китапларны төреп бәйләү. ◇ Паковать чемодан — әйберләрне чемоданга салып бикләп кую.

ПАКО'ВКА *ж. спец.*— 1. төреп бәйләү; 2. *разг.* төрү материалы (мәсәлән, кәгазь, чыпта һ. б.).

ПАКО'ВОЧНЫЙ *спец.*— төрү...-ы; төреп бәйләү...-ы; *паковочный материал* — төреп бәйләү материалы.

ПА'КОСТИТЬ *несов. разг. неодобр.*— 1. шакшылау, пычрату, буяу; 2. бозу, эштән чыгару, яраксыз итү; *пакостить работу* — эшне бозу; 3. әшәкелек эшләү, начарлык эшләү; *пакостить своему соседу* — үзеңнең күршеңә әшәкелек (начарлык) эшләү.

ПА'КОСТИТЬСЯ *несов. страд. простореч.*— 1. шакшылатылу, пычратылу; 2. яраксыз хәлгә китерелү.

ПА'КОСТЛИВЫЙ *простореч.*— шакшы; *пакостливая кошка* — шакшы мәче.

ПА'КОСТНИК *м.*, ПА'КОСТНИЦА *ж. простореч.*— 1. шакшы, шапшак, әшәке кеше; 2. *презрит. (развратник)* женси бозык, женси тотнаксыз кеше.

ПА'КОСТНИЧАТЬ *несов. разг.*—1. *(грязнить, марать)* шакшылату, пычрату, буяу; 2. *(развратничать)* женси тотнаксызлык күрсәтү, бозыклыклар эшләү.

ПА'КОСТНЫЙ — 1. сасы, әшәке; *пакостный запах* — сасы ис; 2. әшәке, шакшы, бозык, әдәпсез; *пакостный человек* — әшәке кеше; *пакостный анекдот* — әдәпсез анекдот.

ПА'КОСТЬ *ж. разг. фам.*— 1. әшәкелек, кабахәтлек; *на моей совести нет ни одной пакости* — минем вөҗданымда бертөрле дә әшәкелек юк; минем вөҗданыма кер төшмәгән; 2. шакшы нәрсә, кабахәт нәрсә; *нельзя есть такую пакость* — мондый шакшы нәрсәне ашарга ярамый; 3. әшәке сүз, әдәпсез сүз; *не говори такую пакость* — мондый әдәпсез сүзне сөйләмә.

ПАКОТИ'ЛЬНЫЙ: пакотильный товар *(спец.)*— 1. арзан товар, түбән хаклы товар; 2. пассажирга (яки судно командасы кешесенә) үзе белән алырга рөхсәт ителә торган товар.

ПАКТ *м. полит.*— пакт (гадәттә зур политик әһәмияте булган халыкара договор); *пакт о ненападении между странами* — илләр арасында һөҗүм итешмәү пакты.

ПАЛ I *м. обл.*— 1. урман, кыр, дала янгыны; 2. янык (урманда, далада, кырда янган урын).

ПАЛ II *м. мор.*— пал (тукталганда судноның арканнары бәйләп куела торган субай, чуеннан ясалган багана).

ПАЛАДИ'Н *м.*— паладин (1. *истор.* Көнбатыш Европада урта йөзләрдә патша сараендагы вельможа; 2. *истор. лит.* урта йөзләрдәге романнарда һәм поэмаларда батыр, баһадир, каһарман рыцарь; 3. *книж. поэт. устар.* берәр фикер, идея өчен көрәшүче).

ПАЛА'НКА *ж. устар.*— паланка (1. *воен.* туфрак өеп ясалган стенасыман ныгытма, казык читән белән ныгытылган урын; 2. Украинада шәһәр янындагы бистә).

ПАЛАНКИ'Н *м.*— паланкин (Көнчыгышта байлар һәм югары катлау кешеләре өчен экипаж хезмәтен үти торган ябык носилка).

ПАЛАНТИ'Н и *устар.* ПАЛАТИ'Н *м.*— палантин (мехтан яки хәтфәдән эшләнгән зур киң шарф).

ПАЛА'С *м.*— палас.

ПАЛА'ТА I *ж.*— палата (1. *только мн. устар.* таштан салынган мәһабәт бина, пулат; *боярские палаты* — бояр палаталары; 2. *устар.* бик зиннәтле итеп төзелеп, аерым максат өчен билгеләнгән зур бина; *Оружейная палата* — Кораллар палатасы; 3. дәвалау йортларында авырулар ята торган бүлмә). ◇ Ума палата *у кого (разг.)* — акыл иясе, бик акыллы кеше, акыл капчыгы.

ПАЛА'ТА II *ж.* — палата (1. СССР Верховный Советын тәшкил иткән һәм закон чыгару хокукына ия булган иң югары учреждение; *Верховный Совет СССР состоит из двух равноправных палат: Совета Союза и Совета Национальностей* — СССР Верховный Советы тигез хокуклы ике палатадан тора: Союз Советы һәм Милләтләр Советы; 2. *полит.* кайбер буржуаз илләрдә вәкилләрдән торган парламент учреждениеләре атамасы; *нижняя палата* — түбәнге палата; *верхняя палата* — югарыгы палата; 3. *офиц.* и *истор.* кайбер дәүләт учреждениеләренең атамасы; *книжная палата* — китаплар палатасы (матбугатта басылып чыккан продукциянең библиографиясен төзеп баручы учреждение); *торговая палата* — сәүдә палатасы).

ПАЛАТАЛИЗА'ЦИЯ *ж. мн.* нет, *лингв.* — нечкәрү, нечкәртелү, палатальләшү, палатальләштерелү; *палатализация согласных* — тартыкларның нечкәрүе (палатальләшүе).

ПАЛАТАЛИЗИ'РОВАННЫЙ *лингв.* — палатальләшкән, нечкәртелгән (сөйләм авазлары турында).

ПАЛАТАЛИЗИ'РОВАТЬСЯ и ПАЛАТАЛИЗОВА'ТЬСЯ *сов.* и *несов. лингв.* — палатальләшү, нечкәрү (сөйләм авазлары).

ПАЛАТА'ЛЬНОСТЬ *ж. мн.* нет, *лингв.* — палатальлек, нечкәлек (сөйләм авазларында)

ПАЛАТА'ЛЬНЫЙ *лингв.* — палаталь, нечкә; *палатальные звуки* — нечкә авазлар.

**ПАЛАТИ'Н** *м. устар.* — к. палантин.

**ПАЛА'ТКА** *ж.* — 1. чатыр, палатка; *разбить палатку* — палатка кору; 2. палатка (а. базарда, урамда вак сәүдә өчен түбәсе ябулы урын; б. *устар.* сәүдә итү рәтләрендә магазин өстендәге вышка; в. *обл* әйберләр саклау өчен булган кечкенә генә таш келәт; г. *истор.* кайбер учреждениеләр атамасы; *пробирная палатка* — пробалау палаткасы — алтынга һәм көмешкә проба куя торган учреждение).

**ПАЛА'ТНЫЙ** — палата... -ы; *палатный врач* — палата врачы.

**ПАЛА'ТОЧНЫЙ** — 1. чатыр өчен яраклы, палатка өчен яраклы; *палаточный холст* — палатка өчен яраклы киндер; 2. палатка...-ы; *палаточная торговля* — палатка сәүдәсе.

**ПАЛА'ТСКИЙ** *устар.* — палата...-ы; *палатский чиновник* — палата чиновнигы.

**ПАЛА'ЦЦО** *ср. нескл.* — палаццо, сарай, дворец; *палаццо венецианских дожей* — Венеция дожлары сарае.

**ПАЛА'Ч** *м.* — җәллад, палач, армай, башкисәр (1. эксплуататорлар җәмгыятендә — үлем һәм тән җәзасын үтәүче кеше; 2. *ритор.* кысучы, каты җәзалаучы, җәфалаучы, палач; *фашисты — палачи не только трудящихся, но и целых народов* — фашистлар хезмәт ияләренең генә түгел, бөтен бер халыкларның да палачлары алар).

**ПАЛА'ЧЕСКИЙ** — палачларча...; җәлладларча...; палач...-ы; *палаческое поведение* — палачларча кыланыш.

**ПАЛА'ЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.* — палачлык, җәлладлык (кысу, җәза бирү, җәзалау, палачларча эш итү).

**ПАЛА'Ш** *м.* — палаш (очы ике йөзле, озын туры кылыч).

**ПАЛЕАЗИА'ТСКИЙ** — к. палеоазиатский.

**ПАЛЕАЗИА'ТЫ** — к. палеоазиаты.

**ПА'ЛЕВЫЙ** — тонык сары, сыек сары төстәге (салам төсендәге); *шёлковое палевое платье* — сыек сары төстәге ефәк күлмәк.

**ПАЛЕНИ'НА** *ж. обл.* — 1. к. паль; 2. өтелгән әйбер исе, көйгән әйбер исе; сөрем исе, көек исе.

**ПАЛЁННЫЙ** — өтелгән.

**ПАЛЁНЫЙ** *разг.* — өтелгән; *палёная свиная туша* — өтелгән дуңгыз түшкәсе; *пахнет палёным* — өтелгән ис килә.

**ПАЛЕО'...** — кушма сүзләрнең „борынгы", „борынгыга караган" мәгънәсендәге беренче кисәге, мәсәлән, *палеоазиатские народности* — борынгы Азия халыклары.

**ПАЛЕОАЗИА'ТСКИЙ** — палеоазиат..., борынгы Азия... -ы; *палеоазиатские народности* — палеоазиат халыклар.

**ПАЛЕОАЗИА'ТЫ** (*ед.* палеоазиат *м.*) — палеоазиатлар (Азиядә һәм Индонезия утрауларында бик борынгы заманнардан бирле яшәп килә торган халыклар).

**ПАЛЕО'ГРАФ** *м.* — палеограф (палеография белгече).

**ПАЛЕОГРАФИ'СТ** *м. спец.* — палеографист (агач һәм бакырга рәсем төшерә торган художник).

**ПАЛЕОГРАФИ'ЧЕСКИЙ** *филол.* — палеография...-ы; *палеографический музей* — палеография музее.

**ПАЛЕОГРА'ФИЯ** *ж. мн.* нет, *филол.* — палеография (1. борынгы кулъязмаларның графикасы һәм тышкы күренеше турындагы фән; 2. нинди дә булса кулъязманың тышкы күренеше һәм язылу үзенчәлекләре; *палеография этого памятника очень своеобразна* — бу памятникның палеографиясе бик үзенчәлекле).

**ПАЛЕОЗА'ВР** *м. палеон.* — палеозавр (казылмаларда гына табыла торган бик зур кәлтә).

**ПАЛЕОЗО'ЙСКИЙ** *геол.* — палеозой...-ы; *палеозойская эра* — палеозой эрасы (җирнең үсеше тарихында мезозой эрасы алдыннан булган эра; бу эра җирдә сөйрәлүче хайваннар барлыкка килү белән характерлана).

**ПАЛЕОЛИ'Т** *м. мн.* нет, *археол.* — палеолит (таш гасырының иң борынгы чоры).

**ПАЛЕОЛИТИ'ЧЕСКИЙ** *археол.* — палеолитик; *палеолитический стиль рисунка* — рәсемнең палеолитик стиле.

**ПАЛЕОНТО'ЛОГ** *м.* — палеонтолог (палеонтология белгече).

**ПАЛЕОНТОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** — палеонтологик; *палеонтологический анализ* — палеонтологик анализ.

**ПАЛЕОНТОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет — палеонтология (хәзерге вакытта казылмаларда гына табыла торган, ташка әверелеп беткән хайваннарны һәм үсемлекләрне өйрәнү фәне). ◇ **Лингвистическая палеонтология или палеонтология языка** — лингвистик палеонтология яки тел палеонтологиясе (тел яшәешенең башлангыч эпохаларындагы кичерешләрне һәм телдә булган башлангыч эпохалар калдыкларын өйрәнә торган лингвистик фән).

**ПАЛЕОТЕ'РИЙ** *м. палеон.* — палеотерий (казылмаларда гына табыла торган тояклы зур хайван, атның иң борынгы бабасы).

**ПАЛЕСТИ'НА** *ж. разг.* — 1. урын, җир, край (күбесенчә, туган җир, туган ил мәгънәсендә); 2. кин, ерак, тын урын.

**ПАЛЕ'ТКА** *ж. спец.* — палетка (план һәм карталардан мәйданның күләмен билгеләү һәм алар буенча копияләр, схемалар төшерү өчен кулланыла торган квадратлар челтәре төшерелгән үтә күренмәле пластинка).

**ПА'ЛЕЦ** *м.* — 1. бармак; 2. (бияләйдә, перчаткада) бармакча; 3. *спец. простореч.* (*зубец на машинном колесе*) теш, тәгәрмәч теше. ◇ **Большой палец** — баш бармак. **Указательный палец** — имән бармак, шәһадәт бармагы. **Средний палец** — урта бармак. **Безымянный палец** — атсыз бармак. **Мизинец** — чәнчә бармак. **Чортов палец** *разг.* — шүрәле бармагы. **Сквозь пальцы смотреть или глядеть** *разг.* — бармак аша карау (берәр җитешсезлекне күрмәмешкә салыну). **Знать как свои пять пальцев** — биш бармагың кебек белү (бик яхшы белү, вагы-төягенә кадәр белү). **Пальцем тронуть** *разг.* — бармак тидерү; *он тебя пальцем не тронет* — ул сиңа бармак та тидермәс

**Палец о палец не ударить** *разг.* — аркылыны буйга салмау (бернәрсә дә эшләмәү). **Пальцем не шевельнуть** *разг.* — бармагын да селкетмәү (бернәрсә дә эшләмәү). **Пальцем показывать** *разг.* — бармак төртеп күрсәтү (берәр кешедән көлеп сөйләү, начар ягын сөйләү). **Как по пальцам** *разг.* — бармак белән санаган кебек (бик җентекләп). **Высосать из пальцев** — к. высосать. **Обвести вокруг пальца** — кәкре каенга терәтү, төпсез чуманга утырту. **Пальца в рот не клади** *разг.* — эләгә күрмә (саклан), кирәгенне бирер. **Попасть пальцем в небо** — к. небо.

**ПАЛЕЯ'** *ж. истор. лит.* — палея (библия риваятьләренең эчтәлекләрен язып аңлатып бирә торган борынгы рус әдәбияты памятникларының атамасы; *палея толковая* — аңлатмалы палея; *палея историческая* — тарихи палея).

**ПА'ЛИВАТЬ** *несов. разг. фам.* — 1. *(палить время от времени)* өткәләү; 2. *(из оружия)* ату, аткалау.

**ПАЛИ'ЛЬНЫЙ** *тех.* — өтү... -ы; *палильная машина* — өтү машинасы.

**ПАЛИ'ЛЬЩИК** *м. спец.* — палильщик, өтүче, көйдерүче, өтү эшендә эшләүче; *палильщик тканей* — тукымалар өтүче (махсус производствода).

**ПАЛИМПСЕ'СТ** *м. филол.* — палимпсест (иң борынгы язуы кырып алынган пергаментка янадан язылган борынгы кулъязма).

**ПАЛИНГЕНЕ'З** и **ПАЛИНГЕНЕ'ЗИС** *м. мн.* нет — палингенез (1. *биол.* үсеш чорында организм югалткан үзенчәлекләрнең организмга кире кайтуы; 2. *филос.* антик философиядә — дөньяның үзлексез янадан туып торуы һәм әүвәл булганнарның һаман кире кайтып торуы турындагы өйрәтмә).

**ПАЛИНДРО'М** *м. лит.* — палиндром (уңнан сулга яки сулдан уңга укыганда да бер үк төрле чыга торган шигырь яки фраза, мәсәлән: аш аша; а Роза упала на лапу Азора).

**ПАЛИСА'Д** *м.* — палисад, рәшәткә (1. *устар.* казыклардан ясалган җинел койма; 2. *воен. истор.* очлы юан бүрәнәләрдән утыртып ясалган оборона корылмасы; 3. *тех.* туфрак өемнәрен ишелүдән саклар өчен сугылган субайлар тезмәсе).

**ПАЛИСА'ДНИК** *м.* — 1. өйтүр бакча (өй каршындагы бакча); 2. *устар.* к. палисад 1; 3. *тех.* палисадник (озынлыгы ярты метрга хәтле, киңлеге 2—4 сантиметрлы кырлы тар такталардан гыйбарәт булган төзү материалы).

**ПАЛИСА'НДР** *м.* — палисандр (тропик илләрдә үсә торган кайбер агачларның кызгылт-көрән, куе ал яки миләүшә төсендәге үзагачы; кыйммәтле мебельләр ясау өчен кулланыла).

**ПАЛИСА'НДРОВЫЙ** — 1. палисандр... -ы; *палисандровая древесина* — палисандр үзагачы; *палисандровое дерево* — палисандр агачы; 2. палисандрдан эшләнгән; *палисандровая кровать* — палисандрдан эшләнгән кровать.

**ПАЛИ'ТРА** *ж.* — палитра (1. художникларның буяу ясау тактасы; 2. *перен книж.* берәр художник яки язучы куллана торган сәнгать чаралары җыелмасы).

**ПАЛИ'ТЬ I** *несов.* — 1. өтү; *палить свиную тушу* — дуңгыз түшкәсен өтү; *палить гуся* — каз өтү; 2. *разг.* яндыру, яндырып бетерү; *палить солому* — саламны яндырып бетерү; 3. *разг.* кыздыру; *солнце палит нестерпимо* — кояш чыдый алмаслык кыздыра; 4. көйдерү, яндыру; *перегретый утюг палит бельё* — артык кызган үтүк керне яндыра. ◇ **Палить зря электричество** — электричествоны юкка яндыру.

**ПАЛИ'ТЬ II** *несов. разг. устар.* — бертуктаусыз ату, залп белән ату; *палить из автомата* — автоматтан бертуктаусыз ату.

**ПА'ЛИЦА** *ж.* — 1. чукмарлы таяк, гөрзи (борынгыда корал урынына кулланылган чукмарлы таяк); 2. *обл.* бәләк (кер чайкаганда керне тукмаклый торган тукмак); 3. сука калагы; 4. *церк.* палица (чиркәүдә гыйбадәт вакытында рухани кия торган киемнең квадрат формасында парчадан эшләнгән бер өлеше).

**ПА'ЛИЯ** *ж. зоол.* — палия (сөләйман балыгы төренә караган, төче суларда була торган балык).

**ПА'ЛКА** ж. — таяк. ◇ **Палка о двух концах** — **таяк ике башлы була. Из-под палки** — к. из-под. **Вставлять палки в колёса** — к. колесо. **Поставить в палки** *устар.* — тукмак астына тыгу (кыйнау, тән җәзасы бирү мәгънәсендә).

**ПАЛЛА'ДИЙ** *м. мн.* нет, *хим.* — палладий (агалтынсыман металл, агалтын белән бергә табыла һәм химик яктан аңа якын тора).

**ПАЛЛА'ДИУМ** *м. мн.* нет, *книж. устар.* — палладиум, яклаучы, терәк (борынгы грекларның ышануы буенча, шәһәрнең курыкнычсызлыгын саклаучы алиһә Афина Паллада сыны булган. Бу сүз шуның исеменнән алынган).

**ПАЛЛИАТИ'В** *м.* — паллиатив (1. *мед.* авыруны җиңми, дәваламый, ләкин вакытлыча җиңеләйтә торган дару; 2. *книж.* авыр хәлдән вакытлыча гына котылып тору өчен эшләнгән ярым-йорты чара).

**ПАЛЛИАТИ'ВНЫЙ** *мед.* и *книж.* — паллиатив...; ярым-йорты; *паллиативное средство* — ярым-йорты чара.

**ПАЛЛОГРА'Ф** *м. мор.* — паллограф (судноның тирбәлешен күрсәтүче яки регистрацияләүче прибор).

**ПАЛО'МНИК** *м.*, **ПАЛО'МНИЦА** *ж.* — 1. *устар.* хаҗи, (христианнарда) паломник (изге дип саналган җирләргә барып гыйбадәт кылучы); 2. *истор. лит.* паломник (борынгы рус әдәбиятында изге дип саналган җирләргә сәяхәтләр ясау турында язылган китаплар исеме); *паломник игумена Даниила* — игумен Даниил паломнигы; 3. паломник (данлыклы урынга яки кешегә килүчеләрдән берәү); *к Льву Толстому в Ясную Поляну являлись отовсюду многочисленные паломники* — Лев Толстойга Ясная Полянага төрле җирләрдән бик күп паломниклар киләләр иде.

**ПАЛО'МНИЧАТЬ** *несов.* — 1. хаҗга бару;

зиарат кылу; паломник булып йөрү; 2. *перен.* (берәр данлыклы җир белән) танышып йөрү, сәяхәт итеп йөрү, сәяхәт кылу.

**ПАЛО'МНИЧЕСТВО** *ср. книж.* — 1. хаж кылу, паломниклык; паломник булып йөрү; 2. *перен. ирон.* (күпләрнең данлыклы берәр җир белән) танышып йөрүе, сәяхәт итеп йөрүе, сәяхәт кылуы.

**ПА'ЛОЧКА** *ж.* — 1. таяк, таякчык; *барабанные палочки* — барабан таяклары; *дирижёрская палочка* — дирижер таякчыгы; 2. *бакт.* таякчык, палочка; *палочка Коха* — Кох таякчыгы (туберкулёз микробы).

**ПА'ЛОЧКОВЫЙ** *спец.* — таяксыман, таякка охшаган; *палочковая форма* — таяксыман форма.

**ПА'ЛОЧНИК** *м.* — 1. *обл.* яшь урман; 2. *биол.* таякчык (тышкы формасы белән агач ботагына охшаган, күбесенчә эссе якларда очрый торган туры канатлы бөҗәк); 3. таяк дисциплинасын яклаучы, таякчы.

**ПА'ЛОЧНЫЙ** — 1. таяк... -ы; *палочная дисциплина* — таяк дисциплинасы; 2. таяк белән...; *палочные удары* — таяк белән сугулар; 3. таяк(лардан ясалган); *палочная изгородь* — таяклардан ясалган киртә.

**ПА'ЛТУС** *м.* — палтус (камбала семьялыгыннан булган төньяк диңгез балыгы).

**ПА'ЛТУСОВЫЙ** — палтус... -ы; *палтусовая икра* — палтус уылдыгы.

**ПА'ЛУБА** *ж.* — палуба (1. судноның һәр катының идәне; *выйти на палубу* — палубага чыгу; 2. *архит.* таш гөмбәзләр салу өчен кружалоларга җәелгән вакытлы такта түшәмә; 3. *спец.* к. палубник).

**ПА'ЛУБИТЬ** *несов. спец.* — такта түшәү (берәр төрле төзелештә, корылмада).

**ПА'ЛУБНИК** *м. мн.* нет, *спец.* — калын такта.

**ПА'ЛУБНЫЙ** *мор.* — 1. палуба... -ы; *палубные доски* — палуба такталары; 2. палубалы; *палубное судно* — палубалы судно; 3. палуба.. -ы; *палубная команда* — палуба командасы.

**ПАЛУ'НДРА** — к. полундра.

**ПА'ЛЫЙ** *обл.* — үлгән (хайван).

**ПАЛЬ** *ж. обл.* — яньк, янган урын (болында, урманда).

**ПАЛЬБА'** *ж. мн.* нет, *разг. устар.* — бертуктаусыз ату, атыш.

**ПА'ЛЬМА** I *ж.* — пальма (эссе якларда үсә торган, ботаксыз, каурыйсыман яки җилпәзәсыман яфраклы агач); *кокосовая пальма* — кокос пальмасы; *финиковая пальма* — хөрмә пальмасы. ◇ **Пальма первенства** *книж.* — беренчелек пальмасы (борынгы грекләрдагы гадәт буенча ярышларда җиңеп чыгучыга пальма ботагы яисә пальма веногы бирелә торган булган; хәзер дә алдын чыгучы турында „беренчелек пальмасын алды" дип әйтелә).

**ПА'ЛЬМА** II *ж. тех.* — пальма (Голландиядә үлчәү берәмлеге — 9,4 *см* га тигез).

**ПАЛЬМЕРСТО'Н** *м. устар.* — пальмерстон (озын пальтоларның бер төре).

**ПАЛЬМЕ'ТТА** *ж. архит.* — пальметта (пальма яфрагы кебек эшләнгән архитектура бизәге).

**ПАЛЬМИ'РА** *ж. мн.* нет, *тип.* — пальмира (типография шрифтларыннан бер гарнитур). ◇ **Северная Пальмира** *устар.* — Төньяк Пальмирасы (Петербургның поэтик атамасы).

**ПАЛЬМИТИ'Н** *м. спец.* — пальмитин (пальма мае һәм башка майлар составына керә торган химик матдә, сабын кайнату һәм шәм кою эшендә кулланыла).

**ПАЛЬМИТИ'НОВЫЙ** *спец.* — пальмитин...-ы; *пальмитиновая кислота* — пальмитин кислотасы.

**ПА'ЛЬМОВЫЙ** — пальма...-ы; *пальмовая ветвь* — пальма ботагы (гадәттә тынычлык, дуслык символы); *пальмовое масло* — пальма мае. ◇ **Пальмовое дерево** *спец.* — пальма агачы (самшит агачының авыр нык үзагачы; гравюралар ую һәм вак-төяк әйберләр ясау өчен кулланыла).

**ПАЛЬНИ'К** *м. воен. устар.* — пальник (атканда тупка пилтә кую өчен кулланыла торган кыскычлы таяк).

**ПАЛЬНУ'ТЬ** *сов. разг.* — атып җибәрү.

**ПАЛЬПА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *мед.* — к. пальпировать.

**ПАЛЬПИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. мед.* — капшап карау (нинди дә булса авыру органны тикшерү өчен капшап карау); *пальпировать брюшную полость* — корсакны капшап карау.

**ПАЛЬПИТА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *мед.* — пальпитация (йөрәкнең еш һәм тигезсез тибүе).

**ПАЛЬТЕЦО'** *ср. мн.* нет, *разг. фам.* — кечкенә пальто, пальто кисәге.

**ПАЛЬТИ'ШКО** *ср. разг. фам. пренебр.* — алама пальто, пальто кисәге.

**ПАЛЬТО'** *ср. нескл.* — пальто; *зимнее пальто* — кышкы пальто; *демисезонное пальто* — язгы-көзге пальто.

**ПАЛЬТО'ЧНИК** *м.*, **ПАЛЬТО'ЧНИЦА** *ж. порт* — пальто тегүче.

**ПАЛЬЦЕВИ'ДНЫЙ** *спец.* — бармаксыман (бармак формасындагы, бармак төсле).

**ПАЛЬЦЕВО'Й** *спец.* — бармак...-ы; *пальцевой сустав* — бармак буыны.

**ПАЛЬЦЕОБРА'ЗНЫЙ** *спец.* — бармакка охшаган, бармаксыман; *пальцеобразные листья* — бармаксыман яфраклар.

**ПАЛЬЦЕХОДЯ'ЩИЕ** *зоол.* — бармакларына басып йөрүчеләр (табаннарына басмыйча, бармакларына гына басып йөрүче хайваннар, мәсәлән, эт, мәче).

**ПА'ЛЬЧАТЫЙ** — 1. *спец.* бармаксыман; *пальчатые листья* — бармаксыман яфраклар; 2. *тех.* тешле; *пальчатый культиватор* — тешле культиватор.

**ПА'ЛЬЧИК** *м. разг.* — бармак, бармакчык. ◇ **Мальчик с пальчик** — к. мальчик. **Пальчики оближешь** — телеңне йотарсың.

**ПА'ЛЬЩИК** *м. спец.* — пальщик (тау токымнарын, тау ташларын шартлату белгече, тау эшчесе).

**ПАЛЯ'ТЬ** *несов. простореч. обл.* — тондыру, бәрү, ыргыту.

**ПАЛЯ'ЩИЙ** — кыздыра торган, яндырып ала торган; *под палящими лучами солн-*

*ца* — кояшның яндырып ала торган нурлары астында.

**ПАМПА'СОВЫЙ** *геогр.*— пампас...-ы, пампасларда үсә (яки яши) торган; ***пампасовая трава*** — пампас үләне; ***пампасовая кошка*** — пампас мәчесе.

**ПАМПА'СЫ** *ед.* нет, *геогр.*— пампаслар (Көньяк Америкада үләнле киң далалар).

**ПАМПУ'ША** *ж. обл.*— 1. пампуша (икенче бер аяк киеме өстеннән киелә торган туфли төре); 2. к. папуша.

**ПАМПУ'ШКА** *ж. обл.*— кабартма.

**ПАМФЛЕ'Т** *м.*— памфлет (берәр кеше турында яки иҗтимагый, политик күренеш турында, агымдагы бурычлар күзлегеннән карап, ачы тәнкыйть белән язылган әсәр, мәкалә, брошюра һ. б.).

**ПАМФЛЕТИ'СТ** *м.*, **ПАМФЛЕТИ'СТКА** *ж. книж.*— памфлетчы (памфлет язучы, памфлетның авторы, памфлет жанрында язучы).

**ПАМФЛЕ'ТНЫЙ** *книж.*— памфлет...-ы; ***памфлетный стиль*** — памфлет стиле.

**ПА'МЯТКА** *ж.*— 1. *разг. устар.* (*нравоучительный случай*) гыйбрәтле вакыйга; 2. *разг. устар.* (*вещь, хранимая на память*) истәлек, ядкарь, хатирә; 3. белешмәлек (кыскача кулланма); 4. истәлек дәфтәре (берәр кешенең эшчәнлеге яки берәр төрле күренекле вакыйга турында кечкенә генә китап).

**ПА'МЯТЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.*— истә тотучанлык, хәтерлелек, зиһенле булу.

**ПА'МЯТЛИВЫЙ** *разг.*— хәтерле, зиһенле, исендә тотучан; ***памятливый человек*** — хәтерле кеше.

**ПА'МЯТНИК** *м.*— 1. һәйкәл; ***в Москве воздвигнут памятник Пушкину*** — Мәскәүдә Пушкинга һәйкәл салынган; 2. кабер ташы; 3. памятник (а. борынгының материаль культура калдыклары; ***археологические памятники*** — археологик памятниклар; б. борынгы язма әсәрләр; ***литературный памятник*** — әдәби памятник; в. халыкның телдән сөйләнеп килгән әсәрләре; ***памятник народного творчества*** — халык иҗаты памятнигы).

**ПА'МЯТНО** *ввод. сл. обл.*— бугай, шикелле; ***она, памятно, сказала (М. Горький)*** — ул әйтте бугай, ул әйтте шикелле.

**ПА'МЯТНЫЙ** — 1. истән чыкмаслык, истә кала торган, хәтердә сакланырлык; ***памятное дело*** — истән чыкмаслык эш; *в знач. сказ.* истән чыга торган түгел; ***это событие всем памятно*** — бу вакыйга беркемнең дә исеннән чыга торган түгел; 2. белешмәләр...-ы; истәлекләр...-ы; ***памятная книжка*** — белешмәләр кенәгәсе; 3. *простореч.* исендә яхшы калдыручан, зиһенле, хәтерле; ***и не грамотен, да памятен*** — укымаган булса да зиһенле.

**ПА'МЯТОВАНЬЕ** *ср. мн.* нет, *книж. устар.*— истә тоту, истә калдыру.

**ПА'МЯТОВАТЬ** *несов. книж. устар.*— истә тоту; ***памятуя это*** — шушыны истә тотып.

**ПА'МЯТЬ** *ж. мн.* нет — 1. хәтер, зиһен, истә калдыру; ис; ***острая память*** — үткен зиһен; ***память может изменить вам*** (*Чернышевский*) — сезнең хәтерегезнең алдавы мөмкин; ***зрительная память*** — күрү хәтере, күреп истә калдыру; ***ушло из памяти*** — истән чыкты, хәтердән чыкты; ***врезаться в память*** — хәтергә сеңеп калу; 2. һуш; ***лишиться памяти*** — һуштан язу; 3. истәлек; ***в память наших встреч*** — безнең очрашулар истәлегенә; ***памяти друга и товарища*** — дусыбыз һәм иптәшебез истәлегенә; ***светлой памяти*** — якты истәлекле; ***печальной памяти*** — күңелсез истәлекле; 4. ядкарь, истәлек; ***подарить на память*** — истәлек (ядкарь) итеп бирү; 5. *разг. церк.* искә төшерү көне, искә алу көне; ***память по отце*** — этине искә төшерү көне; ***сегодня память отца*** — бүген этине искә алу көне. ◇ **Я вас без памяти люблю** — мин сезне шашып яратам. **В памяти** *разг. устар.*— аңында. **На памяти истории** *разг.*— к. история. **По старой памяти** *разг.*— иске гадәт буенча. **По памяти или на память** (рассказывать, говорить, знать и т. п.) — яттан (сөйләү, белү һ. б.). **Прийти на память** — искә төшү. **Куриная память** *разг.*— начар хәтер. **Короткая память** — к. короткий.

**ПАН** *м.*— 1. пан (а. элекке Польша алпавыты; б. революциягә кадәр әфәнде мәгънәсендә кулланылган мөрәҗәгать итү сүзе); 2. *обл. устар.* әфәнде, бояр, хуҗа. ◇ **Либо пан, либо пропал** — я уңам, я туңам; булса булды, булмаса юк; булса булыр, булмаса юк.

**ПАН-...** — пан-... (кушма сүзләрнең „барысын да үз эченә ала торган" мәгънәсендәге беренче кисәге, мәсәлән, панславизм — XIX йөздә һәм XX йөз башларында славян дәүләтләрен патша Россиясе кул астында берләштерергә омтылган реакцион политик агым).

**ПАНА'МА** I *ж.*— панама (киң кырыйлы үреп ясалган эшләпә).

**ПАНА'МА** II *ж.*— панама, зур хыянәт (1. капиталистик предприятиеләрдә зур хыянәт итү; 2. шундый зур хыянәт аркасында предприятиенең бөлүе).

**ПАНАРИ'ЦИЙ** *м. мед.*— панариций (бармакның эренләп шешүе).

**ПАНАЦЕ'Я** *ж.*— 1. *истор.* панацея (алхимикның барлык авыруларны дәвалый торган даруы); 2. *перен. книж. преимущ. ирон.* коткаручы (бар нәрсәдән савыктыручы, барлык очракларда ярдәм итүче чара); ***панацея от всех зол*** — барлык бәлаләрдән коткаручы.

**ПАНБА'РХАТ** *м. мн.* нет — панбәрхет (нәфис, юка бәрхет).

**ПАНДЕ'МИЯ** *ж. мед.*— пандемия, үләт (йогышлы авыруның бик киң таралган эпидемиясе).

**ПА'НДУС** *м. тех.*— пандус (баскыч урынына куела торган сөзәк түшәмә, мәсәлән, гаражларда).

**ПАНЕГИ'РИК** *м.*— панегирик (1. *истор. лит.* мактау сүзе, мактау рече; 2. *перен.*

*книж.* берәр кешене, я берәр нәрсәне кирәгеннән артык мактау, урынсызга мактау, мәдхия уку, күкләргә күтәрү).

**ПАНЕГИРИ'СТ** *м.*, **ПАНЕГИРИ'СТКА** *ж.*— панегирист (1. *истор. лит.* панегирик авторы; 2. *перен. книж.* берәр кешене, я берәр нәрсәне кирәгеннән артык мактаучы).

**ПАНЕГИРИ'ЧЕСКИЙ** *книж.*— панегирик; *панегирическая литература* — панегирик әдәбият; *панегирический тон*— панегирик тон.

**ПАНЕ'ЛЬ** *ж.*— панель (1. урамның ике ягында җәяүлеләр йөрер өчен тротуар; 2. *спец.* бүлмә стенасының аскы өлешен каплаган такта обшивка яки агачка охшатып буялган аскы өлеше; *панель из орехового дерева* — чикләвек агачыннан ясалган панель; 3. радиоалгычның барлык аерым кисәкләрен беркетә торган такта яки калай; 4. җыелма конструкцияләрдән салына торган бина стеналарының һәм түшәмнәренең зур бер кисәге).

**ПАНЕ'ЛЬНЫЙ** — панель...-ы; панельлек; *панельный материал* — панельлек материал.

**ПАНЕ'НКА** *ж. обл. устар.*— туташ, житкән кыз.

**ПА'НИ** *ж. нескл.*— пани (Польшада хатыннарга эндәшү сүзе).

**ПАНИБРА'ТСКИЙ** — әшнәләрчә..., һичбер тартынусыз; тәкәллефсез; *панибратские отношения* — әшнәләрчә мөгамәләләр, һичбер тартынусыз мөгамәлә.

**ПАНИБРА'ТСТВО** *ср. мн.* нет, *разг.*— агай-энечә генә, тартынусыз кыланыш, тәкәллефсез мөгамәлә.

**ПА'НИКА** *ж. мн.* нет — паника (күп кешенең берьюлы куркуга төшүе, каушап калуы).

**ПАНИКАДИ'ЛО** *ср. церк.*— (күп оялы) чиркәү шәмдәле.

**ПАНИКЁР** *м.*, **ПАНИКЁРША** *ж. неодобр.*— паникёр, паникага бирелүче, паника таратучы.

**ПАНИКЁРСКИЙ** *неодобр.*— паникёрларча...; паникёрлык...-ы; *паникёрские действия* — паникёрларча кыланыш; *паникёрское настроение* — паникёрлык настроениесе.

**ПАНИКЁРСТВО** *ср. мн.* нет, *неодобр.*— паникага бирелү, паникёрлык.

**ПАНИКЁРСТВОВАТЬ** *несов. разг. неодобр.*— паникага бирелү, паникёрлык күрсәтү.

**ПАНИХИ'ДА** *ж. церк.*— панихида (җеназа намазы, мәет озату йоласы). ◇ **Гражданская панихида** — гражданлык панихидасы (үлгән кешене күмгәндә үткәрелә торган митинг).

**ПАНИХИ'ДНЫЙ** *разг. шутл. устар. перен.* — төшенке, күңелсез; *панихидное настроение* — төшенке настроение.

**ПАРТРАБО'ТА** *ж. мн.* нет — партия эше.

**ПАРТРАБО'ТНИК** *м.* — партия работнигы, партработник.

**ПАРТСОБРА'НИЕ** *ср.* — партия җыелышы.

**ПАРТСТА'Ж** *м. мн.* нет — партия стажы (КПСС сафында булу стажы).

**ПАРТСЪЕ'ЗД** *м.* — партия съезды.

**ПАРТШКО'ЛА** *ж.* — партия мәктәбе.

**ПАРТЯЧЕ'ЙКА** *ж. устар.* — партия ячейкасы (башлангыч партия оешмасының XVII партсъездга чаклы булган атамасы).

**ПА'РУБОК** *м.* — егет (Украина тормышы турындагы хикәяләрдә кулланыла).

**ПА'РУС** *м.* — 1. җилкән; *поднять* или *поставить паруса* — җилкәннәрне кору; *убрать* или *свернуть паруса* — җилкәннәрне җыю; *идти под парусами* — җилкән корып бару; 2. *спец.* аерым сәүдә судносы; 3. *архит.* кыек яссылык, гөмбәз кырые. ◇ **На всех парусах** *разг. перен.* — бөтен көч белән; җан-фәрманга.

**ПАРУСИ'НА** *ж. мн.* нет — калын киндер, парусина.

**ПАРУСИ'ННЫЙ** и **ПАРУСИ'НОВЫЙ** — калын киндер(дән тегелгән); *парусиновые туфли* — калын киндер туфли; *парусиновые занавески* — калын киндер пәрдәләр.

**ПА'РУСИТЬ** *несов. мор.* — җилгә каршы

тору (пароходның җилгә каршы торуы, җилгә каршылык күрсәтүе).

**ПА'РУСНИК** *м.* — 1. *мор. (парусное судно)* парусник, җилкәнле судно; 2. *спец.* җилкәннәр тегүче.

**ПА'РУСНЫЙ** — 1. җилкән...-ы, җилкәнле; *парусная лодка* — җилкәнле көймә; 2. җилкәнле көймәләр...-ы; *парусный спорт* — җилкәнле көймәләр спорты.

**ПАРФО'РС** *м. спец.* — парфорс (ау этләрен ауга өйрәткәндә кулланыла торган чәнечкеле яки элмәкле муенчак).

**ПАРФЮМЕ'Р** *м.* — парфюмер (1. парфюмерия товарлары хәзерләүче; 2. *устар.* парфюмерия товарлары белән сәүдә итүче).

**ПАРФЮМЕ'РИЯ** *ж. мн.* нет — парфюмерия (1. хушбуй, исле майлар һәм исле сабыннар кебек товарлар; *торговля парфюмерией* — парфюмерия белән сәүдә итү; 2. шундый товарларны эшләп чыгару; 3. *разг.* шундый товарлар сатыла торган магазин).

**ПАРФЮМЕ'РНЫЙ** — 1. парфюмерия...-ы; *парфюмерный магазин* — парфюмерия магазины; 2. *перен. разг. ирон. редко* купшы; *парфюмерный молодой человек* — купшы яшь егет.

**ПАРХ** *м. простореч.* — таз, кутыр (башта).

**ПАРХА'ТЫЙ** *простореч.* — кутырлы, таз кеше.

**ПАРЦЕ'ЛЛА** *ж. экон.* — парцелла, бик кечкенә җир участогы.

**ПАРЦЕЛЛИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. экон.* — җирне бик кечкенә кисәкләргә бүлеп бетерү, җирне бүлгәләү.

**ПАРЦЕЛЛЯ'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *экон. с.-х.* — к. парцеллировать.

**ПАРЧА'** *ж. мн.* нет — парча, чатма (алтын яисә көмеш ука белән бизәкләнгән ефәк тукыма).

**ПАРЧО'ВЫЙ** — парча(дан тегелгән); *парчёвый халат* — парчадан тегелгән халат.

**ПАРША'** *ж. мн.* нет — 1. *мед.* таз, корчаңгы; 2. *простореч.* кутыр, бетчә (тәндә).

**ПАРШИ'ВЕТЬ** *несов. разг. пренебр.* — тазлану, кутырлану, корчаңгылану.

**ПАРШИ'ВЕЦ** *м.*, **ПАРШИ'ВКА** *ж. простореч. фам.* — таз, кабахәт, әшәке, юньсез.

**ПАРШИ'ВИТЬ** *несов. разг.* — таз йоктыру, корчаңгы йоктыру.

**ПАРШИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — корчаңгылылык, тазлык.

**ПАРШИ'ВЫЙ** — 1. кутырлы, таз, корчаңгы; *паршивая лошадь* — корчаңгы ат; 2. *перен. простореч.* бик начар, әшәке, алама; *паршивая история вышла* — бик начар хәл килеп чыкты; 3. *простореч. бран.* юньсез, кабахәт, вахлак; *паршивый человек* — юньсез кеше, кабахәт кеше. ◇ **Паршивая овца всё стадо портит** — тычкак сыер бөтен көтүне буйый.

**ПА'РЯ** *м. мн.* нет, *обл. простореч.* — егет, егеткәй; *эх, ты, паря!* — эх, син, егеткәй!

**ПАС** I — пас (1. карта уенында: карталарның бу тапкыр өләшенүендә „уенга катнашмыйм" мәгънәсендә кулланыла торган сүз; 2. *перен.* „көчем җитми", „хәлемнән килми" мәгънәсендә кулланыла торган сүз; *в этом деле я пас* — бу эшкә минем көчем җитми).

**ПАС** II *спорт.* — пас (спорт уеннарында тупны партнёрга тапшыру).

**ПА'СЕВКИ** и **ПА'СЕВНИ** *ед.* нет, *обл.* — калдык орлык (чәчүдән артып калган орлык).

**ПА'СЕКА** *ж.* — 1. умарталык; 2. киселәсе урман участогы.

**ПА'СЕЧНИК** *м.* — умартачы, умарталыкта эшләүче.

**ПА'СЕЧНЫЙ** *спец.* — умартачылык...-ы; *пасечное хозяйство* — умартачылык хуҗалыгы.

**ПА'СКВИЛЬ** *м.* — 1. пасквиль (берәр кешегә яла ягып, берәр кешене мыскыл итеп язылган әсәр яки рәсем); 2. яла, мыскыллау.

**ПА'СКВИЛЬНЫЙ** — пасквиль...-ы; мыскыллау...-ы; *пасквильный тон* — мыскыллау тоны.

**ПАСКВИЛЯ'НТ** *м. устар.* — пасквилянт (пасквиль язучы, башкалар турында гайбәт таратып йөрүче).

**ПАСКУ'ДА** *ж.* и *м. простореч. вульг. бран.* — әшәке, кабахәт (кеше).

**ПАСКУ'ДИТЬ** *несов. простореч. вульг.* — пычрату.

**ПАСКУ'ДНИК** *м. простореч. вульг.* — әшәке кеше, кабахәт кеше, әшәкелекләр эшләүче.

**ПАСКУ'ДНИЧАТЬ** *несов. простореч. вульг.* — кабахәтлекләр эшләү, әшәкелекләр эшләү.

**ПАСКУ'ДНЫЙ** *простореч. вульг.* — әшәке, кабахәт.

**ПАСКУ'ДСТВО** *ср. мн.* нет, *простореч. вульг.* — кабахәтлек, әшәкелек, әшәке эш.

**ПАСЛЁН** *м. бот.* — эт җиләге (үс). ◇ **Паслён чёрный** — карга борыны (үс.). **Паслён сладко-горький** — саескан җиләге (үс.).

**ПА'СМА** *ж. обл.* — к. пасмо.

**ПА'СМО** *ср. тех.* — басма (бер басма җеп).

**ПА'СМУРНЫЙ** — 1. сүрән, болытлы, салкынкы; *пасмурный день* — салкынкы көн; *пасмурная погода* — болытлы көн; 2. күңелсез, караңгы чырайлы; *пасмурный человек* — күңелсез кеше; *отчего у вас такой пасмурный вид?* — ни өчен сезнең чыраегыз шундый караңгы?

**ПАСНУ'ТЬ** I *сов. разг. фам.* — к. пасовать I.

**ПАСНУ'ТЬ** II *сов. разг. фам.* — к. пасовать II.

**ПАСОВА'ТЬ** I *несов.* — 1. (*в карточной игре*) пас әйтү, уенда катнашмау; 2. *перен.* шүрләп калу, куркып калу, бирешү, үзеңне җиңелгән дип санау; *коммунист не должен пасовать перед трудностями* — коммунист кыенлыклар алдында шүрләп калмаска тиеш; 3. *перен.* калышу, түбән булу; *пасовать в знаниях перед кем-н.* — белемдә кемнән дә булса калышу, кемнән дә булса түбән булу.

**ПАСОВА'ТЬ** II *сов.* и *несов. спорт.* —

тупны (бирү) тапшыру; *пасовать на край* — тупны кырыйда уйнаучыга тапшыру.

**ПАСОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов. спорт. разг.*— тупны бер-берсенә бирешү; *нападающие, пасуясь, прорвались к воротам противника* — һөҗүм итүчеләр, тупны бер-берсенә бирешеп, каршы якның капкасы янына үтеп чыктылар.

**ПА'СОКА** *ж. мн.* нет, *анат. устар.*— к. лимфа.

**ПА'СОЧНИЦА** *ж. спец. устар.*— пасха савыты (эремчектән пасха пешерү өчен кулланыла).

**ПА'СОЧНЫЙ** *спец.*— пасха өчен булган, пасха өчен хәзерләнгән; *пасочный творог* — пасха өчен хәзерләнгән эремчек.

**ПАСПАРТУ'** *ср. нескл. спец.*— паспарту (1. рәсемнәр һәм фотография карточкалары өчен катыргы рамка; 2. рәсем яки карточка ябыштырыла торган катыргы кисәге).

**ПА'СПОРТ** *м.*— паспорт (1. шәхес таныклыгы; *предъявите паспорт* — паспортыгызны күрсәтегез; *прописать паспорт* — паспортны яздыру; 2. *спец.* транспорт һәм хуҗалык әйберләрен регистрацияләп бирелгән документ; *паспорт автомашины* — автомашинаның паспорты; *паспорт станка* — станокның паспорты).

**ПАСПОРТИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *спец.*— 1. паспортизация, паспортлаштыру, паспортлар бирү; *паспортизация населения* — халыкка паспортлар бирү; 2. паспортлар язу (станокларга паспортлар язу системасын кертү); *паспортизация станков* — станокларга паспортлар язу.

**ПАСПОРТИЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. спец.*— паспортизация үткәрү, паспортлар бирү, паспортлар язу.

**ПАСПОРТИЗОВА'ТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— паспортлар бирелү, паспортлар язылу, паспортизация үткәрелү.

**ПАСПОРТИ'СТ** *м.*, **ПАСПОРТИ'СТКА** *ж.*— паспортист (милиция бүлегендә яки йортлар идарәсендә паспортларны язучы, яшәү урынын күрсәтеп регистрацияләүче яки паспорт бирүче хезмәткәр).

**ПА'СПОРТНЫЙ** — паспорт...-ы, паспортлар...-ы; *паспортная система* — паспортлар системасы; *паспортная книжка* — паспорт кенәгәсе.

**ПАСС** *м.* — пасс (гипнотизёрның кешене йоклату өчен ясаган кул хәрәкәтләре).

**ПАССА'Ж** *м.* 1. пассаж (а. ике ягына кибетләр тезелеп киткән пыяла түбәле галерея; *отправляюсь в пассаж за покупками* — пассажга әйберләр сатып алырга барам; б. *муз.* музыкаль фраза, музыкаль әсәрнең виртуоз характердагы кисәге; в. киносценарийда геройларның бер обстановкадан икенче обстановкага күчүләре; г. *спорт.* атта йөрүдәге иң югарыгы осталыкның бер төре, ритмлы хәрәкәтләр ясап атның юргалап баруы; д. *спец.* бактерияләрне бер хайваннан икенче хайванга җибәрү); 2. *разг. устар.* көтелмәгән хәл; *ах, какой пассаж!* (Гоголь) — ах, нинди көтелмәгән хәл!

**ПАССАЖИ'Р** *м.*, **ПАССАЖИ'РКА** *ж.*— пассажир, юлчы.

**ПАССАЖИ'РСКИЙ** — пассажир (лар)...-ы; *пассажирский багаж* — пассажир (лар) багажы; *пассажирское движение* — пассажир поездлар йөреше (хәрәкәте).

**ПАССА'ТНЫЙ** *метеор. геогр.*: **пассатный ветер** — к. пассаты.

**ПАССА'ТЫ** *метеор. геогр.*— пассатлар (тропиклардан экваторга таба өзлексез исеп тора торган коры җилләр).

**ПАССЕИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж. неодобр.*— пассеизм (хәзерге тормышка дошманлык белән янсә илтифатсызлык белән карап, үткән тормышны яклау, үткән тормышка соклану).

**ПАССЕИ'СТ** *м. книж. неодобр.*— пассеист (үткән тормышка сокланучы, пассеизм тарафдары).

**ПАССИ'В** *м. мн.* нет — пассив (1. *бухг.* предприятиенең бөтен бурычлары; 2. *перен. книж.* нинди булса эш яки хәлнең начар ягы; *в пассив учёному нужно записать тяжёлый слог его книги* — галимнең пассивына аның китабының авыр телдә язылуын кертергә кирәк; 3. *грам.* фигыльдә төшем юнәлеше).

**ПАССИВИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. тех.*— пассивлаштыру, пассивировать итү (металлның өстен тутыгу кебек реакцияләргә бирешми торган итеп эшкәртү).

**ПАССИ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— пассивлык; *пассивность характера* — характерның пассивлыгы; *пассивность баланса* — баланс пассивлыгы; *проявлять пассивность* — пассивлык күрсәтү.

**ПАССИ'ВНЫЙ** *книж.*— пассив...; *пассивный человек* — пассив кеше (эштә активлык күрсәтми торган кеше, дәртсез кеше); *пассивный характер* — пассив характер; *играть пассивную роль* — пассив роль уйнау.◇ **Пассивный баланс внешней торговли** — тышкы сәүдәнең пассив балансы (читкә чыгарыла торган товарларның читтән кертелә торган товарлардан азрак булуы). **Пассивная конструкция** *грам.*— пассив конструкция (хәбәре төшем юнәлешендәге фигыль белән белдерелгән җөмлә).

**ПА'ССИЯ** *ж. разг. устар.*— яраткан, яраткан кыз, яраткан егет, мәгъшук, мәгъшука.

**ПАССОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.*— к. пасовать.

**ПА'СТА** *ж.*— паста (косметикада, рәсем ясауда, кулинариядә һ. б. кулланыла торган йомшак камырсыман нәрсә); *зубная паста* — теш пастасы.

**ПА'СТБИЩЕ** *ср.*— көтүлек, көтү йөртү урыны, утлавык.

**ПА'СТБИЩНЫЙ** *с.-х.*— көтүлектә йөртеп..., көтүлектә йөртү...-ы; *пастбищное содержание скота* — хайваннарны көтүлектә йөртеп туйдыру; *пастбищный период* — көтүлектә йөртү чоры (көтүдә йөртү чоры).

**ПА'СТВА** *ж. церк. ритор.*— мәхәллә кешеләре.

**ПАСТЕ'ЛЬ** *ж. живоп.*— пастель (1. рәсем ясау өчен кулланыла торган төсле

(йомшак) карандашлар; 2. шундый карандашлар белән ясалган рәсем).

**ПАСТЕ'ЛЬНЫЙ** *живоп.* — пастель...-ы, пастель белән ясалган; *пастельная живопись* — пастель белән ясалган рәсем.

**ПАСТЕРИЗА'ТОР** *м. спец* — пастеризатор (пастеризацияләү аппараты).

**ПАСТЕРИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *спец.*— пастеризовать итү, пастеризацияләү (сыек әйберне ябык савытта кайнату юлы белән зарарлы микроорганизмнар үрчүдән саклау).

**ПАСТЕРИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. спец.*— к. пастеризация.

**ПАСТЕРИЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. спец.*— к. пастеризировать.

**ПАСТЕРНА'К** *м. мн.* нет — пастернак (яшелчә).

**ПАСТЕ'Т** *м.*— к. паштет.

**ПАСТИ'** *несов.* — көтү (терлекләрне кырда, болында йөртеп ашату); *пасти коров* — сыерларны көтү; *пасти стадо* — көтү көтү.

**ПАСТИЛА'** *ж.*— пастила (җимешкә шикәр кушып кайнатып, куертып ясалган как); *яблочная пастила* — алма пастиласы.

**ПАСТИЛА'Ж** *м.*— пастилаж (1. *тех.* изеп яндырылган балчыктан ясалган скульптура; 2. *кулин.* шикәрдә камырдан берәр фигурага охшатып ясалып пешерелгән ашамлык).

**ПАСТИ'ЛЬЩИК** *м. спец.*— пастилачы (пастила производствосында эшләүче).

**ПАСТИ'СЬ** *несов.*— көтүлектә йөрү, көтүлектә туенып йөрү.

**ПА'СТОР** *м.* — пастор (протестантлар чиркәве рухание).

**ПАСТОРА'ЛЬ** *ж. истор. лит.* — пастораль) көтүчеләр тормышын мактап язган драматик яки музыкаль-идиллик әсәр).

**ПАСТОРА'ЛЬНЫЙ** *лит. муз.*— 1. пастораль...-ы; *пасторальный стиль* — пастораль стиле; 2. пастораль рәвешендә язылган; *пасторальная пьеса*—пастораль рәвешендә язылган сәхнә әсәре.

**ПА'СТОРСТВО** *ср. мн.* нет, *церк.*— пасторлык (пастор эшчәнлеге, пасторлык хезмәте, пасторлык званиесе).

**ПА'СТОРША** *ж. разг.* — пастор хатыны.

**ПА'СТРИГИ** и **ПА'СТРИЖКИ** *ед.* нет, *спец.*— кыркындык (1. сукнодан кыркылган йоннар; 2. куактан, агач ябалдашыннан кыркып алынган ботак очлары).

**ПАСТУ'Х** *м.*—көтүче (көтү көтүче). ◇ **Без пастуха овцы не стадо** — хуҗасыз өй таркалыр.

**ПАСТУ'ШЕСКИЙ** — 1. көтүче...-ы; *пастушеский труд* — көтүче хезмәте; 2. *лит. устар.* көтүчеләр тормышын мактаган; *пастушеские стихи* — көтүчеләр тормышын мактаган шигырьләр.

**ПАСТУ'ШИЙ** — көтүче...-ы; *пастуший кнут* — көтүче чыбыркысы. ◇ **Пастушья сумка** *бот.*— көтүче сумкасы (үсемлек).

**ПАСТУ'ШКА** — *ж.* көтүче кыз (күбрәк идиллияләрдә кулланыла).

**ПАСТУШО'К** *м.* — яшь көтүче, көтүче малай.

**ПАСТУШО'НОК** *м. разг. фам* — к. пастушок.

**ПА'СТЫРСКИЙ** — пастырь...-ы; пастырьлык...-ы; *пастырская должность* — пастырьлык хезмәте.

**ПА'СТЫ'РСТВО** *ср. мн.* нет, *церк.* — пастырьлык (руханилык хезмәте).

**ПА'СТЫРЬ** *м.*— 1. *книж. поэт. устар.* көтүче; 2. *церк.* мәхәллә җитәкчесе, рухани.

**ПАСТЬ** I *сов.* — 1. к. падать 1, 2, 3, 6, 8, 9, 10, 11, 12; 2. *книж.* һәлак булу, үтерелү; *пасть в сражении* — сугышта һәлак булу; 3. җиңелү, дошманга бирелү (шәһәр, крепость); *крепость пала после упорного сопротивления*— крепость зур каршылык күрсәтк ннән соң гына бирелде; 4. төшерелү, бәреп төшерелү; *русское самодержавие пало в 1917 г.* — рус самодержавиесе 1917 елда бәреп төшерелде; 5. авторитетны югалту; *он пал очень низко в глазах всех* — ул барлык кешеләр алдында авторитетын тәмам югалтты; 6. *устар.* фахишәлеккә бирелү (хатын-кыз турында). ◇ **Пасть духом** — к. падать.

**ПАСТЬ** II *ж.*— авыз (ерткыч хайваннарда).

**ПАСТЬ** III *ж. охот. обл.*— капкын, тозак (җәнлек аулар өчен).

**ПАСТЬБА'** *ж. мн.* нет — к. пасти.

**ПА'СХА** *ж.*— пасха (1. *только ед.* яһүдиләрнең һәм христианнарның язгы дини бәйрәмнәре; 2. шушы бәйрәмгә карата эремчектән хәзерләнгән ашамлык).

**ПАСХА'ЛЬНЫЙ** —пасха...-ы; *пасхальные торжества* — пасха тантаналары.

**ПАСЫНКОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. обл. с.-х.* — өзеп, (кыркып) ташлау (үсемлекләрнең кирәкмәгән яшь ботакларын өзеп, яисә кыркып ташлау).

**ПА'СЫНОК** *м.*— 1. үги ул (үги ир бала, үги малай); 2. *с.-х. (у растений)* артык бәбәк, кирәкмәс яшь ботак; 3. *перен.* бәхетсез, артык саналган, үксез, кагылган, кыерсытылган (рәнҗетелгән) кеше; *пасынок жизни* — тормышның үги баласы, бәхетсез кеше.

**ПАСЬЯ'НС** *м.* — пасьянс (уен карталарын билгеле бер кагыйдә буенча таратып төрле фигуралар китереп чыгару); *раскладывать пасьянс* —пасьянс салу; *заниматься пасьянсом* — пасьянс салып утыру.

**ПАСЬЯ'НСНЫЙ** *спец.* — пасьянс...-ы; *пасьянсные карты* — пасьянс карталары.

**ПАСЮ'К** *м. обл.*— күсе, комак.

**ПАТ** I *м. шахм.*— пат (шахмат уенында уйнаучының берсе нинди генә ход ясаса да үзенең королен удар астына куюдан гыйбарәт булган хәл).

**ПАТ** II *м. мн.* нет — пат (җимештән ясалган пастиланың бер төре).

**ПАТЕ'НТ** *м.*— патент (1. берәр һөнәр белән шөгыльләнүгә яки сату итүгә хокук бирә торган таныклык; *торговый патент* — сәүдә патенты; 2. уйлап табучыга үзенең уйлап тапкан әйберенә хокук бирә торган документ, таныклык; *патент на изобретение* — уйлап тапкан әйбәргә патент; 3. *перен.* берәр хокук яки яхшы сыйфат турында таныклык; 4. *право. полит.* судно

хужасына дәүләт флагы күтәрергә хокук бирә торган язу).

**ПАТЕ'НТИКА** *ж. мн.* нет, *собир. спец.*— патентика (патент бирелгән дарулар).

**ПАТЕ'НТНЫЙ** — патент...-ы; *патентное право* — патент хокукы.

**ПАТЕНТО'ВАННЫЙ** — 1. патент бирелгән; патентланган; *патентованное лекарство* — патент бирелгән дару; 2. *перен. презрит.* танылган, чын, чып-чын; *патентованный негодяй* — танылган кабахәт (кеше).

**ПАТЕНТОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. офиц.*— патент бирү яки алу; *патентовать изобретение* — уйлап табылган нәрсәгә патент бирү.

**ПАТЕНТОСПОСО'БНЫЙ** *право.*—патентка лаеклы, патент алуга хаклы, патент бирерлек (патент бирелгәндә куелган таләпләргә җавап бирерлек); *патентоспособное изобретение* — патентка лаеклы булган уйлап табу.

**ПА'ТЕР** *м.*— католик побы, католик рухание.

**ПАТЕ'ТИКА** *ж. мн.* нет, *книж.*— патетика (тәэсирлелек, патетик тон, пафослы, күтәренке тон); *патетика ораторской речи* — оратор сөйләвенең патетикасы.

**ПАТЕТИ'ЧЕСКИЙ** *книж.*— патетик (көчле тәэсир итә торган, рухны күтәрә торган); *патетический стиль* — патетик стиль; *патетическая симфония*— патетик симфония.

**ПАТЕТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— көчле тәэсирлелек, патетик булу.

**ПАТЕТИ'ЧНЫЙ** — к. патетический.

**ПАТЕФО'Н** *м.*— патефон (граммофонның бер төре).

**ПАТЕФО'ННЫЙ** — патефон...-ы; *патефонная пластинка* — патефон пластинкасы; *патефонные иголки* — патефон энәләре.

**ПА'ТИНА** *ж. мн.* нет, *искус. археол.*— кунык (күп вакытлар үтү аркасында бронза өстендә барлыкка килгән көрәнсу-яшел төстәге катлам).

**ПАТИНИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. спец.*— кунык йөгертү (бакырдан һәм бронзадан ясалган әйберләргә борынгылык төсе бирү өчен аларны махсус катлам белән каплау).

**ПАТЛА'СТЫЙ** и **ПАТЛА'ТЫЙ** *просторечи.*— тузгыган, тузган; *патластая голова* — тузган баш.

**ПА'ТЛЫ** *мн. простореч.*— тузгыган чәч, тырпайган чәч.

**ПАТОВА'ТЬ** *несов. шахм.*— пат кую, пат итү (шахмат уенында).

**ПАТОГЕНЕ'З** и **ПАТОГЕНЕ'ЗИС** *м. мн.* нет, *мед.*—патогенез (берәр авыруның барышында эзлеклелек; *патогенез брюшного тифа* — корсак тифының патогенезы).

**ПАТОГ'ЕННЫЙ** *бакт. мед.*— авыру йоктыра торган; *патогенный микроб* — авыру йоктыра торган микроб.

**ПА'ТОКА** *ж. мн.* нет — бәрәңге балы, патока; *варенье на патоке* — патока белән кайнатылган вареньe.

**ПАТО'ЛОГ** *м. мед.*—патолог (патология белгече, врач).

**ПАТОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** *мед.*— 1. патологик; *патологическая анатомия* —патологик анатомия; 2. *перен. книж.* патологик, авырып нормадан тайпылган; *патологическое явление* — авырып нормадан тайпылган күренеш.

**ПАТОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет, *мед.*— патология (организмда була торган авыру процессларын, нормадан читкә тайпылу күренешләрен тикшерә торган фән).

**ПАТОЛОГОАНА'ТОМ** *м. мед.*— паталогоанатом (патологик анатомия белгече).

**ПА'ТОЧНЫЙ** — патока...-ы; *паточное варенье* — патока вареньесы.

**ПАТРИА'РХ** *м.*— патриарх (1. ырулар җәмгыятендә ыру башлыгы; 2. православие чиркәвендә иң югары рухани).

**ПАТРИАРХА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — патриархальлек, борынгылык, искергәнлек, консервативлык; *патриархальность взглядов* — карашларның искергәнлеге.

**ПАТРИАРХА'ЛЬНЫЙ** — 1. *этнол.* патриархаль (ырулар җәмгыяте вакытына караган); *патриархальный быт* — патриархаль көнкүреш; 2. бик борынгы, искергән, артта калган, консерватив; *патриархальные взгляды* —искергән карашлар.

**ПАТРИАРХА'ЛЬЩИНА** *ж. мн.* нет, *публиц. неодобр.*— патриархальщина (патриархаль мөнәсәбәтләр калдыгы).

**ПАТРИАРХА'Т** *м.*—патриархат (1. *этнол.* ырулар җәмгыятенең югары власть патриарх кулында булган формасы; 2. *церк.* патриарх идарә иткән чиркәү).

**ПАТРИА'РХИЯ** *ж. церк.*— патриархия (патриархка буйсынган барлык чиркәүләр, патриарх карамагындагы барлык мәхәлләләр).

**ПАТРИА'РШЕСКИЙ** — патриарх...-ы; *патриаршеское облачение* — патриарх(ның) гыйбадәт киеме.

**ПАТРИА'РШЕСТВО** *ср. церк.*— патриархлык (1. башында патриарх торган чиркәү идарәсе; 2. патриарх званиесе).

**ПАТРИА'РШЕСТВОВАТЬ** *несов. церк.*— патриархлык итү, патриарх булып тору.

**ПАТРИА'РШИЙ** *церк.*— к. патриаршеский.

**ПАТРИМОНИА'ЛЬНЫЙ** *право, социол.*— мираска тигән, мирас булып калган.

**ПАТРИМО'НИЙ** и **ПАТРИМО'НИУМ** *м. право, социол.*— мираска калган милек.

**ПАТРИО'Т** *м.*— патриот (үз халкы, үз ватаны өчен үзен-үзе аямыйча көрәшүче).

**ПАТРИОТИ'ЗМ** *м. мн.* нет — патриотлык, патриотизм (үз иленне, үз халкыңны өзелеп ярату һәм үз Ватаның өчен армый-талмый көрәшергә, хәтта корбан булырга хәзер тору); *советский патриотизм* — совет патриотизмы.

**ПАТРИОТИ'ЧЕСКИЙ** *книж.*— патриотик, патриотлык...-ы; *патриотические чувства советского народа* — совет халкының патриотлык хисләре.

**ПАТРИОТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— патриотлык; *он проявил патриотичность* — ул патриотлык күрсәтте.

**ПАТРИОТИ'ЧНЫЙ** — к. патриотический.

**ПАТРИО'ТКА** *ж.*— патриотка (патриот хатын-кыз).

**ПА'ТРИЦА** *ж. тип.*— патрица (китап басу яки матрица ясау өчен рельефлы форма.

**ПАТРИЦИА'НКА** *ж. истор.*— патрицианка; к. патриций.

**ПАТРИЦИА'НСКИЙ** *истор.* — патриций...-ы, патрицийларга хас.

**ПАТРИЦИА'Т** *м. мн.* нет, *собир. истор.* – патрицийлар.

**ПАТРИ'ЦИЙ** *м. истор.*— патриций (1. борынгы Римда — төп Рим нәселеннән килгән һәм власть башында торган югары сыйныф кешесе; 2. урта йөзләрдә Германия шәһәрләрендә бай бюргерлар нәселеннән булган кеше).

**ПАТРО'Н** I *м.*— патрон (1. *истор.* борынгы Римда — үзенең ирекә җибәрелгән колларын һәм клиентларын яклаучы дип исәпләнгән тулы хокуклы гражданин; 2. капиталистик илләрдә предприятие хуҗасы; 3. *перен. книж. устар.* яклаучы, химаяче).

**ПАТРО'Н** II *м.*— 1. патрон (а. мылтык, револьвер патроны; б. *тех.* кыру һәм бораулау станокларында эшкәртелә торган әйберне станокның әйләнмә кисәгенә беркетеп куя торган җайланма; в. *тех.* электр лампасы борып куела торган патрон; г. тукымага төшереләчәк рәсем трафареты; д. папирос гильзасы); 2. *порт.* өлге, кисү өлгесе; *патрон для мехового воротника* — мех яка кисү өлгесе.

**ПАТРОНА'Ж** *м. мн.* нет, *книж. устар.*— патронаж (1. баланың өй шартларында үсүен һәм тәрбияләнүен махсус медицина учреждениеләренең күзәтеп торулары; 2. ятим калган яки ата-аналарын югалткан балаларны хезмәт ияләре семьяларына договор нигезендә тәрбиягә бирү).

**ПАТРОНА'Т** *м. мн.* нет, *книж.*— 1. патронат (а. борынгы Римда клиентларның материаль яктан патронга бәйле булулары; б. ятим калган яки ата-аналарын югалткан балаларны хезмәт ияләре семьяларына договор нигезендә тәрбиягә бирү); 2. *перен.* яклау, химая, канат астына алу.

**ПАТРОНЕ'ССА** *ж. книж.*— патронесса (1. буржуаз җәмгыятьтә нинди дә булса җәмгыяте хәйрияне тотучы хатын-кыз; 2. гомумән химаяче хатын-кыз).

**ПАТРОНИ'РОВАТЬ** I *несов. книж.*— яклау, химая итү, патронлык итү.

**ПАТРОНИ'РОВАТЬ** II *несов. спец.*— 1. (туку эшендә тукымага төшереләчәк) рәсем трафареты хәзерләү; 2. өлге буенча кисү (тегү эшендә).

**ПАТРО'ННИК** *м. спец.*— патронник (1. мылтыкта һ. б. патрон кертә торган урын; 2. патрон формасына кертү өчен папирос кәгазен чорный торган таякчык).

**ПАТРО'ННЫЙ** — патрон...-ы; *патронный завод* — патрон заводы.

**ПАТРОНТА'Ш** *м. охот. воен.*— патронташ (патроннар сала торган сумка).

**ПАТРО'НША** *ж. разг. ирон.*— патронша, хуҗа хатын.

**ПА'ТРУБОК** *м. тех.* — патрубок, кыска труба, труба кисәге (төп трубадан тармакланып киткән труба кисәге).

**ПАТРУЛИ'РОВАТЬ** *несов. воен.*— патрулировать итү, патрульлек итү, патруль булып йөрү.

**ПАТРУЛИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. воен.*— патрульлек ителү.

**ПАТРУ'ЛЬ** *м. воен.*— патруль (билгеле бер районда тәртипне, куркынычсызлыкны күзәтү өчен билгеләнгән кораллы кечкенә отряд), хәрби самолет яки судно).

**ПАТРУ'ЛЬНЫЙ** *воен.*— 1. патрульлек...-ы; *патрульная служба* — патрульлек хезмәте; 2. патруль..., патрульлек итүче; *патрульный самолёт* — патрульлек итүче самолёт.

**ПА'УЗА** *ж.*— пауза, тыныш ясау (1. сөйләмдә кыска тукталыш; гомумән берәр эшнең тукталып торуы, өзелеп торуы; 2. *муз.* авазның яңгырашында ритмик тәртипкә салынган тукталышлар; *знак паузы* — ритмик тукталыш билгесе; 3. шул тукталышларны күрсәтә торган нота билгеләре).

**ПА'УЗИТЬ** *несов. спец.*— паузокка күчереп төяү.

**ПА'УЗНЫЙ** *муз.*— пауза...-ы; *паузный знак* — пауза билгесе.

**ПА'УЗОК** *м. спец.*— паузок (елга саекканвакытта сай урыннан үтә алмый торган зур судноның йөген күчереп төяү өчен ясалган махсус судно).

**ПАУ'К** *м.*— 1. *зоол.* үрмәкүч; 2. *перен.* соры корт, үрмәкүч, эксплуататор.

**ПАУКООБРА'ЗНЫЙ** *книж. зоол.*— үрмәкүчсыман.

**ПА'УПЕР** *м. социол.*— паупер, үтә ярлы, фәкыйрь.

**ПАУПЕРИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *книж.*— пауперлашу, үтә ярлылану, хәерчеләнү (капиталистик җәмгыятьтә хезмәт ияләренең масса күләмдә фәкыйрьлеккә төшүләре).

**ПАУПЕРИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.*— пауперизм (капиталистик эксплуатация шартларында хезмәт ияләренең фәкыйрьлекләре).

**ПАУТИ'НА** *ж.*— 1. үрмәкүч оясы, пәрәвез; 2. (*паутина, летающая осенью в воздухе*) тоҗым; 3. *перен.* тозак; *опутать паутиной лжи* — ялган тозагына эләктерү.

**ПАУТИ'НКА** *ж. разг.*— кечкенә пәрәвез. ◇ **Чулки паутинка** — бик юка оек.

**ПАУТИ'ННЫЙ** — пәрәвез...-ы; *паутинные нити* — пәрәвез җепләре.

**ПАУ'ЧИЙ** — үрмәкүч...-ы; *паучьи ножки* — үрмәкүч аяклары.

**ПАУША'ЛЬНЫЙ** *спец.*— тулаем алынган; *паушальная сумма* — тулаем алынган сумма.

**ПАФ** *междом.*— шарт! (ату тавышы ымлыгы).

**ПА'ФОС** *м. мн.* нет, *книж.*— пафос, күтәренке рух; *говорить с пафосом* — пафос белән сөйләү; күтәренке рух белән сөйләү.

**ПАХ** *м. анат.*— касык.

**ПА'ХАНЫЙ** — сукаланган, сөрелгән; *паханое поле* — сөрелгән җир.

**ПА'ХАРЬ** *м.* — сабанчы, сукачы, җир сөрүче; *в полях трудятся пахари* (Некрасов) — кырларда сукачылар эшли.

**ПАХА'ТЬ** *несов.* — 1. җир сөрү, сөрү, сукалау (җирне); 2. *устар. (веять, дуть)* исү, исеп тору; 3. *обл.* себерү; *пахать пол* — идән себерү.

**ПАХИТО'СА** и **ПАХИТО'СКА** *ж.* — папирос (кукуруз яфрагын төреп ясалган нечкә папирос).

**ПА'ХНУТЬ** *несов.* — 1. ис килеп тору, аңку, ис килү; *розы приятно пахнут* — розалардан хуш ис аңкый; 2. *разг.* булырга охшау, мөмкин булу, ихтимал; *это дело пахнет большими убытками* — бу эш зур зыянлы булырга охшый; бу эштән зур зыян чыгуы мөмкин; *пахнет бедой* — бәла чыгуы бар. ◇ **Пахнет порохом** — к. порох.

**ПАХНУ'ТЬ** *сов. разг.* — исеп кую (җил); *ветер пахнул* — җил исеп куйды; *с балкона в комнату пахнуло свежестью* (Гончаров) — балконнан бүлмәгә салкынча җил исеп куйды.

**ПАХОВИ'К** *м. обл.* — касыктагы шеш.

**ПАХОВО'Й** и **ПА'ХОВЫЙ** *анат. мед.* — касык...-ы; *паховой канал* — касык каналы; *паховая железа* — кыярак, касык бизе.

**ПА'ХОТА** *ж. мн.* нет, *с.-х.* — сөрү, сукалау.

**ПА'ХОТНИК** *м. просторечь.* — сукачы, җир сөрүче.

**ПА'ХОТНЫЙ** — сөрергә яраклы, иген игәргә яраклы; *пахотная земля* — иген игәргә яраклы җир.

**ПАХОТОСПОСО'БНЫЙ** *книж. с.-х.* — сөрергә, сукаларга яраклы (җир).

**ПА'ХТА** *ж. мн.* нет, *спец.* — май әйрәне (май язганнан соң калган әйрән).

**ПА'ХТАЛКА** *ж. спец. обл.* — гөбе (май язу коралы).

**ПА'ХТАЛЬНЫЙ** *спец.* — май атлау...-ы; май язу...-ы; *пахтальная мутовка* — май атлау калагы, гөбе таягы.

**ПА'ХТАЛЬЩИК** *м.*, **ПА'ХТАЛЬЩИЦА** *ж. спец.* — май атлаучы, май язучы.

**ПА'ХТАНЬЕ** *ср. мн.* нет, *спец.* — 1. май атлау, май язу; 2. май әйрәне (май язганнан соң калган әйрән).

**ПА'ХТАТЬ** *несов. спец.* — май атлау, май язу.

**ПАХУ'ЧЕСТЬ** *ж. мн.* нет — хуш ислелек, ислелек, исле булу.

**ПАХУ'ЧИЙ** — исле, хуш исле, ис аңкып тора торган.

**ПАХУ'ЧКА** *ж.* — исле чәчәк.

**ПАЦИЕ'НТ** *м.* — пациент (врачта дәвалanучы авыру).

**ПАЦИЕ'НТКА** *ж.* — пациентка (врачта дәваланучы хатын-кыз).

**ПАЦИФИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *полит.* — пацифизм (һәртөрле сугышка, хәтта гадел сугышларга — милли азатлык сугышларына һәм революцион сугышларга каршы торган буржуаз агым).

**ПАЦИФИКА'ЦИЯ** *ж. полит.* — пацификация (гаскәр көчләре белән тынычлык урнаштыру, восстаниеләрне, халык күтәрелешләрен бастыру).

**ПАЦИФИ'СТ** *м. полит.* — пацифист (пацифизмны яклаучы, пацифизм карашларында торучы).

**ПАЦИФИ'СТСКИЙ** *полит.* — пацифистларча...; пацифизм...-ы; *пацифистские взгляды* — пацифизм карашлары; *пацифистское поведение* — пацифистларча кылаnыш.

**ПАЦЮ'К** *м.* — к. пасюк.

**ПА'ЧЕ** *книж. церк. устар.*: **тем паче** — бигрәк тә, шуңа күрә дә; **паче чаяния** — уйламаган җирдән, көтмәгәндә, искәрмәстән, уйлаганның киресенчә, көтелгәннең киресенчә.

**ПА'ЧЕСИ** *ед.* нет, *обл.* и *спец.* — чүбек (житен яки киндер сүсен щётка белән икенче кат чистартканда кала торган чүбек).

**ПА'ЧЕЧНЫЙ** *спец.* — пачкалап чыгарыла торган, пачкалы (мәсәлән, товар).

**ПА'ЧКА** *ж.* — 1. пачка, төргәк, бәйләм; 2. пачка (а. *горн.* катламлы пластта берничә янәшә катлам; б. *театр.* балериналарның үтә күренмәле материядән тегелгән һәм сәхнәгә чыкканда кия торган берничә кыска юбкадан гыйбарәт костюмы).

**ПА'ЧКАМИ** *нареч.* — пачкалап.

**ПА'ЧКАНЫЙ** *разг.* — пычрак, пычранган, буялган.

**ПА'ЧКАТЬ** *несов.* — пычрату, шакшылату; *не пачкай платье* — күлмәгеңне пычратма; *не рисует, а только пачкает* — рәсем төшерми, пычрата гына. ◇ **Пачкать репутацию или доброе имя** — исемен пычрату, яла ягу, хур итү. **Руки пачкать** *просторечь.* — кулны пычрату; *не хочется руки пачкать* — кулны пычратасы килми (берәр күңелсез, начар эшкә тыгыласы килми).

**ПА'ЧКАТЬСЯ** *несов.* — шакшылану, караю пычрану; *белые брюки быстро пачкаются* — ак чалбар тиз пычрана. ◇ **Пачкаться не хочется** *перен. разг.* — пычранасы килми (берәр күңелсез, начар эшкә тыгыласы, катнашасы килми).

**ПАЧКОТНЯ'** *ж. мн.* нет, *пренебр.* — пычрату, начар, (пычрак) эшләнгән эш (күбесенчә рәсем ясауда, язу-сызуда); *не картина, а пачкотня* — картина түгел бу, пычрату гына.

**ПАЧКУ'Н** *м.*, **ПАЧКУ'НЬЯ** *ж. разг. фам.* — 1. шапшак, быкырдык; 2. *пренебр.* эшли белмичә эшләүче (бигрәк тә рәсем ясаучы); 3. *пренебр. брач.* эшәке кеше.

**ПА'ЧПОРТ** *м. просторечь.* — к. паспорт.

**ПАША'** *м.* — паша (элекке Төркиядә һәм Мисырда иң олы түрәләр титулы).

**ПАШАЛЫ'К** *м. истор.* — пашалык (элекке Төркиядә паша карамагындагы өлкә).

**ПАШКВИ'ЛЬ**, **ПАШКВИ'ЛЬНЫЙ**, **ПАШКВИЛЯ'НТ** *устар.* — к. пасквиль.

**ПА'ШНЯ** *ж.* — 1. сөрелгән җир, сукаланган җир; 2. *обл.* сука (вакыты), җир сөрү; *скоро пашня начнётся* — тиздән сука башлана, тиздән сукага чыгабыз.

**ПА'ШПОРТ** *м. обл.* — к. паспорт.

**ПАШТЕ'Т** *м. кулин.*— паштет, бәлеш.

**ПА'ЩЕНОК** *м. просторeч. бран.*— малай актыгы, авызыннан сөте кипмәгән малай.

**ПА'ЮС** *м. спец.*— уылдык сүрүе, икра капчыгы.

**ПА'ЮСНЫЙ: паюсная икра** — паюслы икра (сүрүендә килеш тозланган кара икра).

**ПАЯ'ЛЬНИК** *м. тех.*— паяльник (металл әйберләрнең кисәкләрен аккургаш белән паять итү өчен кулланыла торган корал).

**ПАЯ'ЛЬНЫЙ** *спец.*— паять итү...-ы; *паяльная лампа* — паять итү (кургаш коеп ябыштыру) лампасы.

**ПАЯ'ЛЬЩИК** *м. спец.*— паять итүче.

**ПА'ЯНЫЙ** *разг.*— паять ителгән; *паяное ведро* — паять ителгән чиләк.

**ПАЯ'СНИЧАТЬ** *несов. разг.*— шамакайлану, кылану, кыланып кеше көлдерү, мәзәкче булып кылану.

**ПАЯ'ТЬ** *несов.*— кургаш коеп ябыштыру, паять итү (металл әйбернең кисәкләрен эрегән аккургаш белән ябыштыру).

**ПАЯ'Ц** *м.*— 1. *театр. устар.* паяц, цирк клоуны; 2. *перен. неодобр.* шамакай, кыланчык, мәзәкче.

**ПЕВА'ТЬ** *несов. разг.*— җырлаштыргалау, җырлаштыру.

**ПЕВЕ'Ц** *м.*— 1. җырчы, җырлаучы (ир кеше); *оперный певец* — опера җырчысы; 2. *перен.* җырчы, шагыйрь, җырлаучы; *советские поэты — певцы народного счастья* — совет шагыйрьләре — халык бәхете турында җырлаучылар.

**ПЕВИ'ЦА** *ж.*— җырчы, җырлаучы (хатын-кыз).

**ПЕВИ'ЧКА** *ж. разг.*— 1. сайрар кош, сайраучы (кош турында гына); *птичка-певичка* — сайрар кош; 2. *пренебр. устар.* җырчы (әдәпсез эчтәлекле җырлар җырлаучы хатын-кыз); *кафешантанная певичка* — кафешантан җырчысы.

**ПЕВУ'Н** *м. разг.*— 1. җырлаучан, җырларга яратучан, күп җырлаучан; 2. *обл.* әтәч.

**ПЕВУ'НЬЯ** *ж.*— җырларга яратучан, җырлаучан, сайраучан; *певунья-ласточка* — сайраучан карлыгач; *девочка-певунья* — җырларга яратучан кызчык.

**ПЕВУ'ЧЕСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— моңлылык, аһәңлелек; *певучесть мелодии* — көйнең моңлылыгы.

**ПЕВУ'ЧИЙ** — көйле, моңлы, аһәңле; *певучая мелодия* — моңлы көй; *певучий голос* — аһәңле тавыш.

**ПЕ'ВЧЕСКИЙ** *спец.*— 1. җырчылар...-ы; хорда җырлаучылар...-ы; *певческая капелла* — җырчылар капелласы; хорда җырлаучылар капелласы; 2. җырлау...-ы; *певческие способности* — җырлау сәләте.

**ПЕ'ВЧИЙ** — 1. сайрый торган, сайрар (кош); *певчие птицы* — сайрар кошлар; 2. *церк.* певчий (чиркәү хорында катнашып җырлаучы); 3. *устар.* гомумән җырчы.

**ПЕГА'С** *м. миф.*— канатлы ат (борынгы грек мифологиясе буенча канатлы ат; бу ат типкән урыннан шагыйрьләргә илһам бирүче Ипокрен чишмәсе бәреп чыккан имеш). ◇ **Оседлать Пегаса** *книж. шутл.*— шигырьләр яза башлау.

**ПЕ'ГИЙ** — ала, чуар, алмачуар (ат төсе).

**ПЕДАГО'Г** *м.*— педагог (укытучы, тәрбияче, уку-укыту, тәрбия эшләрен алып баручы, педагогика белгече).

**ПЕДАГО'ГИКА** *ж. мн.* нет — педагогика (укыту һәм тәрбияләү методлары турындагы фән).

**ПЕДАГОГИ'ЧЕСКИЙ** — педагогик; педагогия...-ы; *новые педагогические кадры* — яңа педагогик кадрлар; *педагогический институт* — педагогия институты; *педагогическое училище* — педагогия училищесы.

**ПЕДАГОГИ'ЧКА** *ж. разг. устар.*— педагогичка (педагогия факультетында укучы хатын-кыз, педагогик курсларда укучы хатын-кыз).

**ПЕДАГОГИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— педагогика таләпләренә яраклылык.

**ПЕДАГОГИ'ЧНЫЙ** *книж.*— педагогикага туры килерлек, педагогика таләпләренә җавап бирерлек.

**ПЕДАГО'ГИЯ** *ж. мн.* нет, *книж.*— педагогия (балаларны тәрбияләү һәм укыту).

**ПЕДАЛИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— 1. *муз.* педаль куллану (пианинода уйнаганда теге я бу авазны ачык чыгару өчен педальгә басу); 2. *перен. книж.* басым ясау, аеруча әһәмиятлелеген күрсәтү, беренче планга кую; *в очерке педализирован мотив расслоения деревни* — очеркта авылның катлаулану мотивы беренче планга куелган.

**ПЕДА'ЛЬ** *ж. тех.*— педаль, тәбәлдерек (машинада һәм музыкаль инструментларда аяк белән басып механизмны хәрәкәткә китерү өчен ясалган җайланма; *велосипедная педаль* — велосипед педале; *фортепьянная педаль* — фортепьяно педале).◇ **(Слишком сильно) нажать педаль** *книж. перен.* — педальгә басу, педальгә артыграк басу, арттырып җибәрү (берәр эшне ассызымлап күрсәткәндә яки берәр кешегә басым ясаганда).

**ПЕДА'ЛЬНЫЙ** *спец.*— 1. педаль...-ы педальгә...; *педальный нажим* — педальгә басу; 2. педальле; *педальный автомобиль* — педальле автомобиль (балалар өчен).

**ПЕДА'НТ** *м.*, **ПЕДА'НТКА** *ж. книж-неодобр.* — педант (1. үз фәненнән башка бернәрсә дә белергә теләмәүче галим, формалист; хәрефкә ябышып ятучы галим; 2. *устар.* үзенең галимлеге белән мактанучы кеше, башкаларга акыл сатучы кеше; 3. тәртипнең бөтен ваклыкларына бирелгән, артык аккуратлык күрсәтүче, вакчыл кеше).

**ПЕДАНТИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж. неодобр.*— педантлык, педантизм (педантча кылану, педантча фикерләү).

**ПЕДАНТИ'ЧЕСКИЙ** *книж. неодобр.*— педантларча...; *педантический подход* — педантларча мөнәсәбәт.

**ПЕДАНТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж. неодобр.*— педантлык.

**ПЕДАНТИ'ЧНЫЙ** *книж. неодобр.*— бик вакчыл; *педантичный человек* — бик вакчыл кеше.

**ПЕДА'НТСКИЙ** *книж. неодобр.* — педант...-ы, педантлык...-ы; педантларча...; *педантское отношение к делу* — эшкә педантларча мөнәсәбәт.

**ПЕДА'НТСТВО** *ср. мн.* нет, *книж. неодобр.*— педантлык (педантка хас фикерләү, кылану, педантларча эшләү).

**ПЕДА'НТСТВОВАТЬ** *несов. книж. неодобр.*— педант булу, үзен педантларча тоту, педантларча фикерләү, педантларча кылану.

**ПЕДВУ'З** *м.*— педагогия югары уку йорты.

**ПЕ'ДЕЛЬ** *м. дореворл.* — педель (университетта студентлар өстеннән карап торучы надзиратель).

**ПЕДИА'ТР** *м. мед.*— педиатр (педиатрия белгече, балалар авырулары врачы).

**ПЕДИАТРИ'ЧЕСКИЙ** *мед.*— педиатрия... -ы; *педиатрическая клиника* — педиатрия клиникасы.

**ПЕДИАТРИ'Я** *ж. мн.* нет, *мед.*— педиатрия (балалар авырулары турында өйрәтмә; шул авыруларны дәвалау).

**ПЕДИКЮ'Р** *м. мн.* нет — педикюр (аяктагы тырнакларны һәм сөялләрне кисү, чистарту; *я сделал себе педикюр* — мин педикюр ясаттым).

**ПЕДИКЮ'РША** *ж.* — педикюрша (педикюр ясаучы хатын-кыз).

**ПЕДИНСТИТУ'Т** *м.*— пединститут (урта мәктәпләр өчен укытучылар хәзерли торган югары уку йорты).

**ПЕДО'ЛОГ** *м.*— педолог (педология белән шөгыльләнүче).

**ПЕДОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** — педологик...; *педологические извращения* — педологик бозулар.

**ПЕДОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет — педология (балаларның язмышлары башта ук биологик һәм социаль факторларга, нәселдәнлек тәэсиренә һәм ниндидер үзгәрми торган мохитка бәйләнгән дип расслый торган, антимарксистик положениеләргә нигезләнгән буржуаз ялган фән).

**ПЕДО'МЕТР** *м. спец.*— педометр, адым үлчәгеч (автоматик рәвештә адым санын билгели торган аппарат).

**ПЕДПРА'КТИКА** *ж. мн.* нет — педпрактика (педагогия уку йортлары студентларының мәктәпкә барып практика узулары).

**ПЕДТЕ'ХНИКУМ** *м. истор.*— педтехникум (педагогия техникумы — хәзерге педучилище).

**ПЕДУЧИ'ЛИЩЕ** *ср.*— педучилище (педагогия училищесы; башлангыч мәктәпләр өчен укытучылар хәзерли торган урта уку йорты).

**ПЕДФА'К** *м.*— педфак (педагогия факультеты).

**ПЕ'ЖИНА** *ж. обл. спец.*— 1. чуарлык; 2. кашка, чуар тап (чуар атның тиресендә ак яки кара тап).

**ПЕЗЕ'ТА** *ж.* — пезета (Испаниядә акча берәмлеге).

**ПЕЙЗА'Ж** *м.*— 1. *книж.* пейзаж, табигать күренеше; *взорам путников открылся чудный пейзаж* — юлчылар күз алдында искиткеч матур табигать күренеше ачылды; 2. *живоп.* пейзаж, табигать күренешләрен сурәтләп биргән картина (рәсем); 3. *лит.* пейзаж, (әдәби әсәрләрдә) табигать күренешләрен сурәтләп бирү; *пейзаж в романах Тургенева* — Тургенев романнарында пейзаж.

**ПЕЙЗАЖИ'СТ** *м.*, **ПЕЙЗАЖИ'СТКА** *ж.*— пейзажист, пейзажчы (1. *живоп.* пейзажларны, табигать күренешләрен рәсемгә төшерүче художник; 2. *лит.* үзенең әдәби әсәрләрендә табигать күренешләрен талантлы рәвештә сурәтләп бирүче язучы; *Тургенев один из лучших русских пейзажистов* — Тургенев иң яхшы рус пейзажчыларыннан берсе).

**ПЕЙЗА'ЖНЫЙ** *живоп.*— пейзажлы, табигать күренешләрен сурәтләгән; *пейзажная картина* — пейзажлы картина, табигать күренешләрен сурәтләгән картина.

**ПЕЙЗА'Н** и **ПЕЙЗА'НИН** *м.*— крестьян, авыл кешесе.

**ПЕЙЗА'НКА** *ж.*— крестьянка, авыл хатынкызы.

**ПЕЙЗА'НСКИЙ** — авыл...-ы; *пейзанские костюмы* — авыл костюмнары.

**ПЕК** *м. тех.*— пек (дегетне, сумаланы, нефтьне һ. б. эшкәрткәндә кала торган куе матдә).

**ПЕКА'РИТЬ, ПЕКА'РНИЧАТЬ** *несов. разг. обл.*— икмәк пешерүче булып хезмәт итү, икмәк пешерүче булып эшләү.

**ПЕКА'РНЫЙ** *спец.*— икмәк пешерү...-ы; *пекарное ремесло* — икмәк пешерү һөнәре; *пекарная печь* — икмәк пешерү миче.

**ПЕКА'РНЯ** *ж.*— пекарня, икмәк пешерү йорты.

**ПЕ'КАРСКИЙ** — икмәк пешерүче...-ы; *пекарский фартук* — икмәк пешерүче алъяпкычы.

**ПЕ'КАРЬ** *м.*— икмәк пешерүче.

**ПЕКЛЕВА'НКА** *ж. мн.* нет, *спец.*: иләнгән он (күбесенчә вак итеп тарттырылган һәм иләнгән арыш оны).

**ПЕКЛЕВА'ННИК** *м. спец. обл.*— вак итеп тарттырылган һәм иләнгән арыш онынннан пешерелгән икмәк.

**ПЕКЛЕВА'ННЫЙ** *спец.*— 1. вак (итеп) тарттырылган һәм иләнгән (күбесенчә, арыш оны); 2. вак (итеп) тарттырылган оннан пешерелгән.

**ПЕКЛЕВА'ТЬ** *несов. спец.*— вак итеп тарттыру һәм иләү (күбесенчә арыш онын).

**ПЕ'КЛО** *ср. мн.* нет, *разг.* — 1. иң эссе җир, бик каты эсселек, кояш эссесе; *сидит на самом пекле* — иң эссе җирдә утыра; 2. *перен. разг.* (сугышның, бәхәснең һ. б. ш. о.) иң кызу барган урыны; 3. *обл.* тамуг, тамуг уты.

**ПЕЛЕНА'** *ж.*— 1. *устар.* (*покров, покрывало*) җәймә, ябма; 2. *перен. книж.* пәрдә; *сплошная пелена облаков* — куе болытлар пәрдәсе. ◇ (Словно) пелена (с глаз) упала (или спала) — күзе ачылып китте (үз хатасын аңлаган, кинәт дөреслекне белеп алган кеше турында әйтелә). От пелён или с пелён

*устар.*— балачактан бирле, сабый чактан бирле.

**ПЕЛЕНА'ТЬ** *несов.*— биләү (баланы).

**ПЕ'ЛЕНГ** *м. спец.*— пеленг (әйбернең күренү, тавышның ишетелү, электромагнит дулкыннарының килү юнәлеше белән компас стрелкасы юнәлеше арасындагы почмак).

**ПЕЛЕНГА'ТОР** *м. спец.*— пеленгатор (пеленглау приборы).

**ПЕЛЕНГА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *спец.*— пеленговать.

**ПЕЛЕНГИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— к. пеленговать.

**ПЕЛЕНГОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. спец.*— пеленгын билгеләү, пеленглау, пеленговать итү (берәр нәрсәнең пеленгын билгеләү); *пеленговать плывущую льдину* — йөзә торган бозны пеленговать итү.

**ПЕЛЁНКА** *ж.*— биләү, биләүсә. ◇ **Из пелёнок** *перен.*— сабый чакта, сабый чактан. **С пелёнок** *перен.*— бала чактан ук, сабый чактан ук.

**ПЕЛЕРИ'НА** *ж.*— пелерина (1. кием өстеннән ябыла торган капюшонлы кыска накидка; 2. хатын-кызларда: кием өстеннән куела һәм кулбашына яки терсәккә хәтле төшеп тора торган киң яка).

**ПЕЛЕ'СИНА** *ж. простореч. обл.*— тимгел, чуар тап (хайван тиресе өстендә булган тимгелләр, икенче төстәге чуар таплар); *шкура рыси вся в пелесинах (Даль)* — селәүсен тиресе чуар таплар белән капланган.

**ПЕЛЁСЫЙ** *простореч. обл.*— чуар, тимгелле.

**ПЕЛИКА'Н** *м. зоол.*— пеликан, баба кошы (озын борынлы һәм томшык астында капчыгы булган су кошы).

**ПЕЛЬКО'МПАС** *м. спец. мор.*— пелькомпас (пеленглау өчен кулланыла торган компас).

**ПЕЛЬМЕ'НИ** *м. кулин.*— пилмән.

**ПЕ'МЗА** *ж. мн.* нет, *спец.*— пемза, күбек таш (тишекле-тишекле бик җиңел вулканик матдә).

**ПЕМЗОВА'ТЬ** *несов. спец.*— пемзалау, пемза белән чистарту, пемза белән шомарту.

**ПЕМЗОВЩИ'К** *м. спец.*— пемзалаучы (берәр нәрсәне пемза белән шомартучы яки чистартучы оста).

**ПЕ'НА** *ж. мн.* нет — күбек. ◇ **С пеной у рта** или **с пеной на устах** *разг.*— авызыннан төкерекләр чәчрәтеп, бик нык кызып.

**ПЕНА'Л** *м.*— пенал (карандаш, каләм тартмасы).

**ПЕНА'ТЫ** *ед.* нет, *книж. поэт. устар.*: **вернуться к пенатам** или **к родным пенатам** или **к своим пенатам** — туып-үскән өйгә кайту.

**ПЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. җырлау, көйләү, сайрау (кош), кычкыру (әтәч); 2. җыр; *учиться пению* — җырга өйрәнү; *учитель пения* — җыр укытучысы.

**ПЕ'НИСТЫЙ** — күбекле.

**ПЕНИТЕНЦИА'РНЫЙ** *право* — пенитенциар, төрмәгә ябып төзәтү...-ы; *пенитенциарная система* — пенитенциар система (төрмәгә ябып бозыклыктан төзәтү системасы).

**ПЕ'НИТЬ** *несов. книж.*— күбекләндерү; *пенить квас* — квасны күбекләндерү.

**ПЕ'НИТЬСЯ** *несов.*— 1. күбекләнү; *реки пенится* — елга күбекләнә; 2. *страд.* күбекләндерелү.

**ПЕНИЦИЛЛИ'Н** *м. мед.*— пенициллин (күгәрек гөмбәсенең кайбер төрләреннән алына торган дару).

**ПЕ'НКА** I *ж.*— яры (кайнап суынган сыеклык, мәсәлән, сөт өстендә пәрдәләнеп каткан куе катлам); *снять пенку с молока* — сөтнең ярысын алу. ◇ **Снимать пенки** *перен. разг. устар.*— каймагын гына ялап алу. **Уж пенки сняты** — туйдан соң дөмбергә.

**ПЕ'НКА** II *ж. мн.* нет — тау күне, тау кәгазе, тау бөкесе (тәмәке трубкалары ясау һ. б. өчен кулланыла).

**ПЕ'НКА** III *ж.* — к. пеночка.

**ПЕ'НКОВЫЙ** — тау күненнән ясалган; *пенковая трубка* — тау күненнән ясалган трубка.

**ПЕ'ННИ** *ср. нескл.*— 1. пенни (фин акчасы берәмлеге); 2. к. пенс.

**ПЕ'ННЫЙ** *книж.*— күбекле, күбекләнгән, күбек белән капланган.

**ПЕ'НОЧКА** *ж.*— чебенче (кош).

**ПЕНС** *м.*— пенс (инглиз акчасы, фунт стерлингның ике йөз кырыктан бер өлешен тәшкил итә).

**ПЕНСИО'Н** *м. офиц. устар.*— пенсион (1. пенсия; 2. берәр кешегә даими рәвештә акчалата ярдәм биреп тору).

**ПЕНСИОНЕ'Р** *м.*— пенсионер (пенсия алучы).

**ПЕНСИОНЕ'РКА** *ж.*— пенсионерка (пенсия алучы хатын-кыз).

**ПЕНСИО'ННЫЙ** *офиц.*— пенсия...-ы; *пенсионная книжка* — пенсия кенәгәсе.

**ПЕ'НСИЯ** *ж.*— пенсия (билгеле бер вакыт буенча хезмәт иткән кешеләргә, хезмәт итеп картайган яки гарипләнгән кешеләргә ай саен бирелеп бара торган акча).

**ПЕНСНЕ'** *ср. нескл.*— пенсне (күзлекнең бер төре).

**ПЕНТАГОНА'ЛЬНЫЙ** *мат.*— пентагональ, биш почмаклы.

**ПЕНТАГРА'ММА** *ж.*— пентаграмма, биш-почмаклык.

**ПЕНТА'МЕТР** *м. лит.*— пентаметр (шигырь үлчәве).

**ПЕНТА'ЭДР** *м. мат.*— пентаэдр, биш кырлык, биш кырлы фигура.

**ПЕ'НТЮХ** *м. простореч. бран.* и *ирон.*— 1. хөрәсән, хөрәсән ялкавы, сөрхантәй, мәнсез; 2. *обл.* корсак.

**ПЕНЬ** *м.*— төп, агач төбе (кисеп алынган агачның җирдә калган өлеше). ◇ **Стоять как пень** или **пнём** *разг.*— утын агачы кебек катып тору. **Стать в пень** *разг. устар.*— шак кату, шак катып калу. **Через пень колоду** *простореч.*— к. колода.

**ПЕ'НЬЕ** и **ПЕНЬЁ** I *ср. мн.* нет, *обл.*— агач төпләре; *топить печь пеньём* — мичкә агач төпләре ягу.

**ПЕНЬЁ** II *ср мн.* нет, *простореч. устар.* и *обл.*— жырлау.

**ПЕНЬКА'** *ж. мн.* нет — киндер сүсе, пәже.

**ПЕНЬКО'ВЫЙ** — киндер сүсеннән эшләнгән (ишелгән); *пеньковый канат* — киндер сүсеннән ишелгән аркан.

**ПЕНЬКОПРЯДЕ'НЬЕ** *ср. мн.* нет, *тех.*— киндер сүсен эрләү.

**ПЕНЬКОПРЯДИ'ЛЬНЫЙ** *тех.*— киндер сүсен эрләү...-ы; киндер сүсен эрли торган; *пенькопрядильная машина* — киндер сүсен эрләү машинасы.

**ПЕНЬКОТРЕПА'ЛЬНЫЙ** *тех.*— киндер талку...-ы; *пенькотрепальная машина* — киндер талку машинасы.

**ПЕНЬКОТРЕПА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *тех.*— киндер талку.

**ПЕНЬЮА'Р** *м.*— пеньюар (1. *спец.* чәч алганда, чәчне тараганда җилкәгә ябыла торган япма; 2. *устар.* өйдә кия торган хатын-кыз күлмәге).

**ПЕ'НЯ** *ж.*— 1. пеня (договор белән алынган берәр эшне яки закон буенча йөкләмәләрне вакытында үтәмәгән өчен алына торган штраф); 2. *устар.* үпкә, күңел калу, хәтер калу.

**ПЕНЯ'ТЬ** *несов.*— үпкәләү, зарлану. ◇ **Нечего на зеркало пенять, коли рожа крива** — авызың чалыш булса, көзгегә үпкәләмә.

**ПЕ'ПЕЛ** *м. мн.* нет — көл. ◇ **Посыпать пеплом главу** *книж.*— бик зур кайгыга бирелү, зур хәсрәткә төшү.

**ПЕПЕЛИ'ЩЕ** *ср. книж.*— 1. янгын хәрабәсе, зур янгыннан калган урын; 2. *перен. (родной очаг)* әби-бабай туфрагы, ата-бабадан калган йорт-җир.

**ПЕ'ПЕЛЬНИЦА** *ж.*— көл савыты, көллек (тәмәке төпчеге ташлау һәм тәмәке көлен кагып төшерү өчен хезмәт итә торган савыт).

**ПЕ'ПЕЛЬНЫЙ** — 1. көл...-ы; *пепельная масса* — көл массасы; 2. *(о цвете)* аксыл соры *(төс)*.

**ПЕПЕРМЕ'НТ, ПЕПЕРМИ'НТ** *м. мн.* нет — пепермент (йөткерүдән дару).

**ПЕПИНЬЕ'РКА** *ж. дореВол.*— пепиньерка (ябык урта уку йортын — хатын-кызлар институтын — бетереп, шунда педагогия практикасына калдырылган кыз).

**ПЕПСИ'Н** *м. спец.*— пепсин (ашказаны бизләре тарафыннан эшләп чыгарыла һәм аш сеңдерүгә ярдәм итә торган органик матдә).

**ПЕРВА'Ч** *м. мн.* нет, *спец.*— беренче сортлы товар.

**ПЕРВЕ'ЙШИЙ** *разг.*— иң беренче, иң яхшы; *товар первейшего сорта* — иң яхшы сортлы товар.

**ПЕ'РВЕНЕЦ** *м. книж.*— 1. *(первый ребёнок)* беренче бала; 2. беренче...-ы; (билгеле бер вакыт эчендә салынган заводларның, электростанцияләрнең һ. б.) беренчесе; *эта книга — мой первенец* — бу китап — минем беренче китабым; *Сталинградский тракторный завод — первенец первой пятилетки* — Сталинград трактор заводы — беренче бишьеллыкта салынган заводларның беренчесе.

**ПЕ'РВЕНСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.*— беренчелек, алдынгылык.

**ПЕ'РВЕНСТВОВА'ТЬ** *несов. книж.*— беренче урында тору, алдынгы булып тору.

**ПЕРВЕНСТВУ'ЮЩИЙ** *книж.*— 1. алдынгылыкны алып торучы, беренче урында торучы; 2. иң мөһим, иң кирәкле.

**ПЕРВЕ'ЮЩИЙ** *просторец.*— к. первейший.

**ПЕРВИ'НКА** *ж. обл.*— беренче (тормышта, бу елда беренче булган әйбер); *вот яблоки - первинки* — менә беренче алмалар. ◇ **В первинку** *разг.*— беренче мәртәбә; *мне не в первинку дрова колоть* — минем утын яруым беренче мәртәбә түгел.

**ПЕРВИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— беренчел булу, беренчеллек; *первичность материи, вторичность сознания* — материянең беренчеллеге, аңның икенчеллеге.

**ПЕРВИ'ЧНЫЙ** 1. беренче, беренчел; *первичный период болезни* — авыруның беренче (беренчел) чоры; 2. башлангыч; *первичная парторганизация* — башлангыч партоешма; 3. нигез, төп; *первичные половые признаки* — төп җенси билгеләр.

**ПЕРВОАПРЕ'ЛЬСКИЙ** — беренче апрель...-ы; *первоапрельская шутка* — беренче апрель мәзәге.

**ПЕРВОБЫ'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— борынгылык, артта калганлык, культурасызлык, кыргыйлык.

**ПЕРВОБЫ'ТНЫЙ** — 1. *науч.* борынгы; *первобытный коммунизм* — борынгы коммунизм; *первобытное общество* — борынгы җәмгыять; 2. культура үсешенең иң түбәнге баскычында торган; *первобытные племена в Австралии* — Австралиядә культура үсешенең иң түбәнге баскычында торган кабиләләр; 3. *палеон.* борынгы (үлеп беткән борынгы хайваннар турында); *первобытный бык (тур)* — борынгы үгез; 4. *перен. книж. неодобр.* культурасыз, артта калган, кыргый; *первобытные нравы* — кыргый гадәтләр.

**ПЕРВОГО'ДОК** *м. разг.*— бер яшь тулмаган (бала яки яшь хайван); *жеребёнок-первогодок* — бер яшь тулмаган колын.

**ПЕРВОЗДА'ННЫЙ** *книж. поэт.*— иң беренче, борынгы, мәңгедән бирле яшәп килгән.

**ПЕРВОЗИ'МЬЕ** *ср. мн.* нет, *обл.*— кыш башы.

**ПЕРВОИСТО'ЧНИК** *м. книж.*— беренче чыганак, төп чыганак.

**ПЕРВО'Й** *просторец.*— к. первый. ◇ **Не в первой** — беренче тапкыр түгел.

**ПЕРВОКАТЕГО'РНИК** *м. спорт.*— беренче категорияле (мәсәлән, физкультурник, шахматчы).

**ПЕРВОКЛА'ССНИК** *м.*, **ПЕРВОКЛА'ССНИЦА** *ж.*— беренче класс укучысы.

**ПЕРВОКЛА'ССНОСТЬ** *ж. мн.* нет — беренче дәрәҗәдә булу.

**ПЕРВОКЛА'ССНЫЙ** — 1. беренче класс-

лы; беренче класс...-ы; 2. иң яхшы, беренче дәрәҗәдәге, мена дигән.

**ПЕРВОКУ'РСНИК** *м.*— беренче курс студенты.

**ПЕРВОКУ'РСНИЦА** *ж.*— беренче курс студенткасы.

**ПЕРВОЛЕ'ТЬЕ** *ср. мн.* нет, *обл.*— җәй башы.

**ПЕРВОМА'Й** *м. мн.* нет, *ритор. поэт.*— Беренче май бәйрәме.

**ПЕРВОМА'ЙСКИЙ** — Беренче май...-ы; ***первомайская демонстрация*** — Беренче май демонстрациясе.

**ПЕ'РВО-НА'ПЕРВО** *простореч.*— барыннан да элек, башта, иң элек.

**ПЕРВОНАЧА'ЛО** *ср. книж.*— башлангыч, төп, асыл, нигез.

**ПЕРВОНАЧА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— башлангыч булу, иң беренче булу.

**ПЕРВОНАЧА'ЛЬНЫЙ** *книж.*— иң беренче, башлангыч, баштагы, башлангыч чордагы.

**ПЕРВОО'БРАЗ** *м. книж.*— беренче үрнәк, оригинал, прототип.

**ПЕРВООБРА'ЗНЫЙ** *книж.*— иң беренче, баштагы.

**ПЕРВООСНО'ВА** *ж. книж.*— төп башлангыч, нигез, асыл; ***материя — первооснова всего существующего*** — материя — бөтен галәмнең асылы ул.

**ПЕРВООТКРЫВА'ТЕЛЬ** *м.*— беренче тапкыр ачучы, беренче булып ачучы (нинди дә булса җирләрне, илләрне, урыннарны ачучы сәяхәтче).

**ПЕРВООЧЕРЕДНО'Й** — беренче чираттагы, беренче чиратта башкарыла торган.

**ПЕРВООЧЕРЁДНОСТЬ** *ж. мн.* нет — беренче чиратта башкарылырга тиешлек, беренче чираттагылык; ***первоочерёдность этой задачи*** — бу бурычның беренче чиратта башкарылырга тиешлеге.

**ПЕРВООЧЕРЁДНЫЙ** — к. первоочередной.

**ПЕРВОПЕЧА'ТНИК** *м. истор.*— беренче башлап китап бастыручы, типография эшен беренче башлап җибәрүче.

**ПЕРВОПЕЧА'ТНЫЙ** *филол.*— 1. *истор.* Россиядә китап басу эшенең башлангыч чорында басылган; 2. типографиядә беренче тапкыр басылган; ***первопечатный текст „Евгения Онегина"*** — „Евгений Онегин"-ның типографиядә беренче тапкыр басылган тексты.

**ПЕРВОПРЕСТО'ЛЬНЫЙ** *книж. ритор. истор.*— иң карт башкала булган; ***первопрестольный город*** — иң карт башкала булган шәһәр.

**ПЕРВОПРИСУ'ТСТВУЮЩИЙ** *офиц. истор.*— (берәр коллегиаль учреждениедә) председательлек итүче; ***первоприсутствующий в департаменте правительствующего сената*** — хакимлек итүче сенат департаментында председательлек итүче.

**ПЕРВОПРИЧИ'НА** *ж. книж.*— төп сәбәп, баш сәбәп, беренче сәбәп.

**ПЕРВОПУ'Т** *обл.* и **ПЕРВОПУ'ТОК** *м. разг.*— яңа төшкән чана юлы.

**ПЕРВОРАЗРЯ'ДНИК** *м. спорт.*— беренче разрядлы (спортның нинди дә булса төре буенча беренче разряд алган кеше).

**ПЕРВОРАЗРЯ'ДНЫЙ** — 1. (*относящийся к первому разряду*) беренче разрядлы; 2. (*первоклассный*) иң яхшы, иң шәп.

**ПЕРВОРО'ДНЫЙ** *книж. устар.*— беренче туган (бала).◇ **Первородный грех** *ирон.*— беренче гөнаһ (иң беренче, иң зур хата турында әйтелә). **Первородный кал** *спец.*— яңа туган баланың беренче көннәрдәге тизәге.

**ПЕРВОРО'ДСТВО** *ср. мн.* нет, *право истор.*— 1. *устар.* яшь ягыннан олылык (ир туганнарга карата); 2. *перен.* (берәр нәрсәнең уйлап табылу, уйлап чыгарылу вакытына карата алганда) беренчелек, беренче урында тору.

**ПЕРВОРОДЯ'ЩАЯ** *спец.*— беренче мәртәбә бала тудыручы (бала табучы хатын)

**ПЕРВОРОЖДЁННЫЙ** *книж. устар.*— башкалардан алда туган (бала).

**ПЕРВОСО'РТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — беренче сорт булу, иң яхшы сортлы булу; беренче сортлылык.

**ПЕРВОСО'РТНЫЙ** — 1. иң яхшы сорт..., беренче сорт..., беренче сортлы; ***первосортный товар*** — беренче сорт товар; 2. *разг.* бик шәп, бик яхшы; ***первосортный писатель*** — бик шәп язучы.

**ПЕРВОСТАТЕ'ЙНЫЙ** *устар.*— 1. *истор.* беренче разрядка керә торган, беренче дәрәҗәдәге, югары дәрәҗәдәге; 2. бик шәп, бик әйбәт; ***первостатейный товар*** — бик шәп товар. ◇ **Первостатейный нахал** — чиктән ашкан нахал, ашып узган нахал.

**ПЕРВОСТЕПЕ'ННЫЙ** *книж.*— беренче урындагы, беренче дәрәҗәдәге, иң мөһим.

**ПЕРВОТЁЛКА** *ж. с.-х.*— беренче бозау анасы, тана сыер.

**ПЕРВОТЕ'ЛЬНАЯ** *ж. с-х.*— беренче мәртәбә бозаулый торган (сыер).

**ПЕРВОЦВЕ'Т** *м. бот.*— науруз (нәүрүз) чәчәге.

**ПЕ'РВЫЙ** — 1. беренче, баштагы; 2. иң яхшысы, иң күңеллесе, барыннан да яхшырагы.◇ **Первым делом** — к. дело. **Первое дело** *простореч.* — к.первым делом. **Первое время** *разг.*— башта. **Влетит ему по первое число** — бик каты эләгер аңа, кирәген бирерләр аның. **Не первой молодости** *ирон.*— шактый картайган. **Не первой свежести** *ирон.*— шактый искергән. **В первую голову** — к. голова. **Первый блин комом** — к. блин. **Первая скрипка** — беренче скрипка (а. оркестрда җитәкче скрипка; б. *перен.* берәр эштә җитәкчелек роле уйный торган кеше).

**ПЕРГА'** *ж. мн.* нет — чиршын, икмәк (саф бал эчендә була торган балавызсыман ачы төер).

**ПЕРГА'МЕН** *м. мн.* нет — к. пергамент 1, 2.

**ПЕРГА'МЕННЫЙ** *филол.*— пергаменга

үтү, бер-бер артлы күз алдына китерү; *он перебрал все события минувших дней* — ул үткән көннәрдә булган барлык вакыйгаларны бер-бер артлы исенә төшерде; 4. *простореч.* сүтеп яңадан ясау (салу); *перебрать избу* — өйне сүтеп яңадан салу; 5. *тип.* яңадан җыю (хәрефләрне); 6. *разг.* (аз-азлап алып яки кисәкләп алып) җыю; *я перебрал товаров на тысячу рублей* — мин мең тәңкәлек товар җыйдым; 7. *разг.* (*взять лишнего*) кирәгеннән артык алу (берәр нәрсәне), кирәгеннән артык җыю. ◇ **Перебрать струны гитары** — гитара кылларына чиртеп чыгу. **Перебрать чётки** *рел.* — тәсбих тарту.

**ПЕРЕБРА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — **1.** күченү, күчү; *перебраться на новую квартиру* — яңа квартирага күчү; 2. аркылы чыгу, кичү; *перебраться через ручей* — инеш аркылы чыгу; 3. күчеп утыру, икенче җиргә барып утыру.

**ПЕРЕБРЕСТИ'** *сов. разг.* — акрын гына аркылы чыгу; *перебрести через мост* — акрын гына күпер аркылы чыгу.

**ПЕРЕБРИВА'ТЬ** *несов. разг.* — к. перебрить.

**ПЕРЕБРИВА'ТЬСЯ** *несов. разг.* — к. перебриться.

**ПЕРЕБРИ'ТЬ** *сов. разг.* — (барысының да сакал-мыекларын) кырып чыгу, кырып бетерү.

**ПЕРЕБРИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — кырынып бетү; *все перебрились* — барысы да кырынып беттеләр.

**ПЕРЕБРОДИ'ТЬ** I *сов. простореч.* — **1.** (ятьмә белән балык) сөзеп йөрү (күлдә, елгада, инештә, буада); 2. (күп урында) булу, (күп урынны) йөреп чыгу; *по всем здешним лесам перебродил* — биредәге барлык урманнарны йөреп чыктым.

**ПЕРЕБРОДИ'ТЬ** II *сов.* — **1.** әчеп житү, кабарып житү; *пиво перебродило* — сыра әчеп житкән; 2. (*прокиснуть*) артык әчеп китү; артык әчеп бозылу; 3. *перен. разг.* акылга утыру (дуамал тормыштан соң); *к тридцати годам он перебродил* — утыз яшьләрендә ул акылга утырды.

**ПЕРЕБРОСА'ТЬ** *сов.* — ыргытып бетерү; *он перебросал все камни в воду* — ул барлык ташларны суга ыргытып бетерде.

**ПЕРЕБРО'СИТЬ** *сов.* — **1.** (берәр нәрсә аркылы) ташлау, ыргыту; *перебросить мяч через забор* — тупны койма аркылы ыргыту; 2. *разг.* (тиешеннән) ераграк ыргыту (ыргытуда башкалардан уздыру); *он перебросил камень на 10 шагов* — ул ташны 10 адымга ераграк ыргытты; *он меня перебросил* — ул миннән ераграк ыргытты; 3. салу, асу (мәсәлән, аркага); *перебросить мешок через плечо* — капчыкны кулбаш аша салу; 4. күчерү, күчереп урнаштыру (бер урыннан икенче урынга); *перебросить дивизию на левый фланг* — дивизияне сул флангка күчерү; *перебросить работников на периферию* — работникларны периферияга күчерү; *перебросить товар из складов в магазины* — товарны складлардан магазинга күчерү. ◇ **Перебросить мост через реку** — елга аркылы күпер салу.

**ПЕРЕБРО'СИТЬСЯ** *сов. разг.* — **1.** (берәр нәрсә аша) сикереп чыгу; *переброситься через забор* — койма аркылы сикереп чыгу; 2. (бер урыннан икенче урынга) ташлану; *отряд перебросился на другой берег реки* — отряд елганың икенче ягына ташланды; 3. *перен.* (берәр нәрсә аша) күчү, сикерү; *огонь перебросился через две избы* — ут ике йорт аша сикерде; 4. *перен. устар.* (дошман ягына) чыгу; *переброситься к неприятелю* — дошман ягына чыгу; 5. ыргытышу; *переброситься мячом* — туп ыргытышу; 6. *перен.* әйтешеп алу; *переброситься несколькими словами* — берничә сүз әйтешеп алу.

**ПЕРЕБРО'СКА** *ж.* — күчерү (бер урыннан икенче урынга); *переброска войск* — гаскәрләрне күчерү; *переброска товаров* — товарларны күчерү.

**ПЕРЕБРЫ'ЗГАТЬ** *сов.* — чәчрәтеп бетерү; *ты всех нас перебрызгал* — син барыбызга да чәчрәтеп бетердең.

**ПЕРЕБРЫ'ЗГИВАТЬ** I *несов. разг.* — к. перебрызнуть.

**ПЕРЕБРЫ'ЗГИВАТЬ** II *несов.* — к. перебрызгать.

**ПЕРЕБРЫ'ЗНУТЬ** *сов. разг.* — (берәр нәрсә аша) чәчрәү; *волна перебрызнула через лодку* — дулкын көймә аша чәчрәде.

**ПЕРЕБУДИ'ТЬ** *сов.* — (барысын да) уятып бетерү; уятып чыгу; *перебудить всех в доме* — өйдәгеләрнең барысын да уятып бетерү (уятып чыгу).

**ПЕРЕБУ'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. перебудить.

**ПЕРЕБУНТОВА'ТЬ** *сов. разг.* — (барысын да) бунтка күтәрү, фетнәгә күтәрү.

**ПЕРЕБЫВА'ТЬ** *сов.* — **1.** (бар җирдә яки күп җирдә) булу; *перебывать у всех знакомых* — барлык танышларда да булу; 2. (төрле вакытта күп кеше) булу, булып китү; килеп китү; *у меня перебывали все сослуживцы* — барлык хезмәттәшләрем миндә булып киттеләр.

**ПЕРЕБЫ'ТЬ** *сов. простореч.* — (ничек туры килсә шулай) яшәү, көн итү.

**ПЕРЕВА'Л** *м.* — (тау сырты аша) үтү, (тау сырты аша) күчү; *перевал через горный хребет был назначен в 6 часов утра* — тау сырты аша үтү иртәнге 6 сәгатькә билгеләнгән иде; 2. үткел, кичү (тау сырты аша үтү юлы); 3. *с.-х.* (*глубокая вспашка*) тирән сөрү (җирне).

**ПЕРЕВА'ЛЕЦ** *м. разг. фам.* — кечкенә генә перевал. ◇ **С перевальцем (ходить)** *разг. фам.* — алпан-тилпән (йөрү).

**ПЕРЕВА'ЛИВАТЬ** I *несов.* — к. перевалить.

**ПЕРЕВА'ЛИВАТЬ** II *несов. разг.* — к. перевалять.

**ПЕРЕВА'ЛИВАТЬСЯ** I *несов.* — **1.** к. перевалиться; 2. *страд.* бер урыннан икенче урынга төялү.

**ПЕРЕВА'ЛИВАТЬСЯ** II *несов. страд. разг.* — яңадан басылу (кнез һ. б.).

**ПЕРЕВАЛИ'ТЬ** *сов. разг.* — **1.** күчерү, күчереп кую, күчереп төяү; *перевалить сено с возу на воз* — печәнне бер йөктән

икенче йөккә күчереп төяү; 2. кичү, үтү; *перевалил какой-то хребет и увидел перед собой голубой океан* (Пришвин) — ниндидер тау сыртын кичте дә үз алдында зәңгәр океан күрде; 3. (бер ярдан икенче ярга) кичү; 4. *разг. безл.* узып киту, ашу; *перевалило за полночь* — ярты төн дә узып китте. ◇ **Ему перевалило за сорок** — ул кырыктан узды инде, ул кырыктан ашты инде.

ПЕРЕВАЛИ'ТЬСЯ *сов.*—1. (берәр нәрсә аркылы) тәгәрәп чыгу, (берәр нәрсә аркылы) тәгәрәү, (берәр нәрсә аркылы) чыгу; *перевалиться через забор* — койма аркылы чыгу; 2. әйләнеп яту; *перевалиться на другой бок* — икенче якка әйләнеп яту. ◇ **Май уже перевалился за вторую половину** (Тургенев) — майның икенче яртысы башланды инде, майның беренче яртысы үтте инде.

ПЕРЕВА'ЛКА *ж. спец.*—1. к. перевалить 1; *перевалка грузов* — йөкләрне күчереп төяү; 2. йөкне күчереп төяү пункты. ◇ **В перевалку (идти)** *простореч.*— алпан-тилпән (бару).

ПЕРЕВА'ЛОЧНЫЙ *спец.*— йөкне күчереп төяү...-ы; *перевалочный пункт* — йөкне күчереп төяү пункты.

ПЕРЕВАЛЯ'ТЬ *сов. разг.*—1. егып бетерү, егып чыгу; *борец перевалял всех противников* — көрәшче үзенә каршы көрәшүчеләрнең барысын да егып бетерде; 2. аунатып бетерү, әвәләп чыгу; *перевалять в грязи* — пычракта аунатып бетерү; *перевалять в муке все пирожки* — барлык сумсаларны онда әвәләп чыгу; 3. яңадан басу (мәсәлән, киезне).

ПЕРЕВАЛЯ'ТЬСЯ *сов. разг.*— 1. аунап пычранып бетү; *перваляться в грязи* — пычракта аунап пычранып бетү; 2. катнашып бетү, киезләнеп бетү (йон турында).

ПЕРЕВА'Р *м. мн.* нет, *разг.*— артык пешеп бозылу.

ПЕРЕВА'РИВАТЬ *несов.*— к. переварить.

ПЕРЕВА'РИВАТЬСЯ *несов.*—1. к. перевариться; 2. *страд.* кирәгеннән артык пешерелү.

ПЕРЕВАРИ'МЫЙ *спец.*— үзләштерелә торган, сеңә торган (ашказанында); *легко переваримая пища* — (ашказанында) җиңел үзләштерелә (сеңә) торган аш.

ПЕРЕВАРИ'ТЬ *сов.*—1. икенче тапкыр пешерү, яңадан пешерү; яңадан кайнату; *переварить засахарившееся варенье* — шикәрләнгән вареньены яңадан кайнату; 2. утта яңадан кыздыру (тимерне); 3. кирәгеннән артык пешерү; кирәгеннән артык пешереп бозу; 4. (ашказанында) сеңдерү, үзләштерү (ашны); 5. *перен. разг.* үзләштерү, төшенү; *не переварил как следует того, что прочитал* — укыган нәрсәсен яхшылап төшенмәгән, үзләштермәгән; 6. *перен. разг. фам.* түзеп, чыдап тору (берәр нәрсәгә); *не мог переварить его присутствия* — ул аның шунда булуына түзми иде. ◇ **Он его не переваривает** *разг. фам.*— ул аны һич яратмый.

ПЕРЕВАРИ'ТЬСЯ *сов.*—1. артык пешеп киту, кирәгеннән артык пешеп бозылу; *мясо переварилось* — ит артык пешеп киткән, итнең пешүе артып киткән; 2. үзләштерелү, сеңү (ашказанында); *пища хорошо переварилась* — аш яхшы үзләштерелде (ашказанында яхшы сеңде).

ПЕРЕВАРНО'Й *простореч. обл.*—1. кайнаган; *переварная вода* — кайнаган су; 2. берничә мәртәбә кайнатылган (мәсәлән, кофе).

ПЕРЕВЕВА'ТЬ *несов.*— к. перевеять.

ПЕРЕВЕ'ДАТЬСЯ *сов. устар.* — үч алу, үч кайтару, кирәген бирү.

ПЕРЕВЕДЕ'НИЕ *ср. мн.* нет, *книж. устар* — күчерү, күчереп урнаштыру.

ПЕРЕВЕ'ДЫВАТЬСЯ *несов. устар.* — к. переведаться.

ПЕРЕВЕЗТИ' *сов.* — 1. күчерү, китерү, илтү (атта, машинада); *перевезти вещи с дачи в город* — әйберләрне (атта, машинада) дачадан шәһәргә күчерү; 2. (аркылы) чыгару (бер җирдән икенче җиргә); *перевезти путников через реку* — юлчыларны елга аркылы чыгару.

ПЕРЕВЕ'ИВАТЬ *несов.* — к. перевеять.

ПЕРЕВЕНЧА'ТЬ *сов. простореч. устар.*— никахландыру.

ПЕРЕВЕНЧА'ТЬСЯ *сов. простореч. устар.* — никахлану, никахланышу, никах укыттыру.

ПЕРЕВЕРНУ'ТЬ *сов.* — 1. әйләндереп кую, йөзтүбән каплау; *перевернуть бочку вверх дном* — мичкәне йөзтүбән каплау; 2. *разг.* әйләндерү; *перевернуть пиджак* — пиджакны әйләндерү; 3. *разг. фам.* бору; *перевернуть дело в свою пользу* — эшне үз файдаңа бору; 4. *разг. фам.* бик нык ачуландыру, ачуны кабарту; *его в его перевернуло от этих слов* — бу сүзләр аның ачуын бик нык кабартты, бу сүзләрдән аның ачуы бик нык кабарды; 5. борып бозу; *перевернуть кран* — борып (артык борып) кранны бозу.

ПЕРЕВЕРНУ'ТЬСЯ *сов.* — 1. әйләнү (бер яктан икенче якка); *перевернуться с боку на бок* — бер яктан икенче якка әйләнү; 2. каплану, йөзтүбән каплану (әйләнү); *лодка перевернулась* — көймә капланды. ◇ **Перевернется в гробу** — үлгән җиреннән сикереп торыр.

ПЕРЕВЕРСТА'ТЬ *сов.* — 1. *тип.* үзгәртеп биткә салу, яңадан биткә салу; 2. *устар.* (*наделить снова*) яңадан бирү, яңача бирү (айлык хезмәт хакын, поместьены һ. б.).

ПЕРЕВЁРСТЫВАТЬ *несов.* — к. переверстать.

ПЕРЕВЁРСТЫВАТЬСЯ *несов. страд.* — үзгәртеп биткә салыну, яңадан биткә салыну.

ПЕ'РЕВЕРТЕНЬ *м. обл.* — 1. убыр; 2. мөртәт.

ПЕРЕВЕРТЕ'ТЬ *сов. разг.* — 1. бора-бора бозу; *перевертеть кран* — бора-бора кранны бозу; 2. (борып чыгарып) яңадан борып кую; 3. *фам.* әйләндереп-әйләндереп карау; тоткалап карау (әйберләрне бер урыннан икенче урынга сала-сала).

ПЕРЕВЕРТЕ'ТЬСЯ *сов. разг.* — борылып бозылу; *винт перевертелся* — борылып винт бозылган.

**ПЕРЕВЁРТЫВАТЬ** I *несов.* — к. перевернуть.

**ПЕРЕВЁРТЫВАТЬ** II *несов. разг.* — к. перевертеть.

**ПЕРЕВЁРТЫВАТЬСЯ** I *несов.* — к. перевернуться.

**ПЕРЕВЁРТЫВАТЬСЯ** II *несов. разг.* — к. перевертеться.

**ПЕРЕВЕ'РЧИВАТЬ** *несов. разг.* — к. перевертеть.

**ПЕРЕВЕ'РЧИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. перевертеться.

**ПЕРЕВЕ'С** *м. мн.* нет — 1. *разг.* к. перевесить 1, 2; 2. *простореч.* (үлчәүдә) артыгы, (үлчәүдә) артканы; *за перевес я доплачу* — (үлчәүдә) артыгы өчен түләрмен; 3. өстенлек, күпчелек; артыклык; *перевес на нашей стороне* — өстенлек безнең якта; *перевес голосов* — тавышларның күпчелеге.

**ПЕРЕВЕ'СИТЬ** *сов.* — 1. яңадан үлчәү, икенче тапкыр үлчәү (авырлыгын); *перевесить муку* — онны яңадан үлчәү; 2. күчереп элү, (бер җирдән алып) икенче җиргә элү; *перевесить картину* — картинаны (икенче бер җиргә) күчереп элү; 3. авыр тарту, авыррак тарту; *одна чашка весов перевесила другую* — үлчәү тәлинкәсенең берсе икенчесеннән авыррак тартты; 4. *перен.* өстен чыгу; *это мнение перевесило все остальные предложения* — бу фикер башка барлык тәкъдимнәрдән өстен чыкты.

**ПЕРЕВЕ'СИТЬСЯ** *сов.* — салынып яту; *перевеситься через перила* — култыксага салынып яту; *перевеситься через борт лодки* — көймә кырыена салынып яту.

**ПЕРЕВЕ'СКА** *ж. мн.* нет, *простореч.* — к. перевесить 1.

**ПЕРЕВЕСТИ'** *сов.* — 1. күчерү (бер урыннан икенче урынга); *перевести больного в другую палату* — авыруны икенче палатага күчерү; 2. аркылы чыгару, чыгарып кую; *перевести слепого через улицу* — сукыр кешене урам аша чыгарып кую; *перевести через мост* — күпер аша чыгарып кую; 3. (почта яки телеграф белән) җибәрү; *перевёл деньги отцу по почте* — этигә почта белән акча җибәрдем; 4. тәрҗемә итү; *перевести роман с русского на татарский язык* — романны рус теленнән татар теленә тәрҗемә итү; 5. *разг.* кырып бетерү, үтереп бетерү; *перевести крыс* — күселәрне кырып бетерү; 6. *разг.* туздыру, әрәм-шәрәм итү; *зря деньги перевёл* — акчаны юкка әрәм-шәрәм иткәнсең. ◇ **Перевести дух или дыхание** — тын алу, ял итү, хәл җыю.

**ПЕРЕВЕСТИ'СЬ** *сов.* — 1. күчү (икенче бер җиргә, икенче бер эшкә); 2. *разг.* бетү, юк булу, югалу; *у него деньги ещё не перевелись* — аның акчасы бетмәгән әле; *пушной зверь не переведётся в наших лесах* — безнең урманнарда кыйммәтле тиреле җәнлекләр бетмәс.

**ПЕРЕВЕ'ШАТЬ** *сов.* — 1. *разг.* элеп бетерү, элеп чыгу; *перевешать всё бельё* — барлык керләрне элеп чыгу; 2. асып үтереп бетерү; *перевешать шпионов* — шпионнарны асып үтереп бетерү; 3. үлчәп чыгу, үлчәп бетерү; *перевешать всю муку* — барлык онны үлчәп чыгу; 4. *разг.* яңадан үлчәп чыгу (авырлыгын); *перевешать весь вновь прибывший товар* — әле генә килгән товарның барысын да яңадан үлчәп чыгу.

**ПЕРЕВЕ'ШИВАТЬ** I *несов.* — к. перевесить.

**ПЕРЕВЕ'ШИВАТЬ** II *несов.* — к. перевешать.

**ПЕРЕВЕ'ШИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. перевеситься; 2. *страд.* яңадан үлчәнү.

**ПЕРЕВЕ'ЯТЬ** *сов.* — икенче кат җилгәрү, яңадан җилгәрү, яңадан суырту (ашлыкны).

**ПЕРЕВИВА'ТЬ** *несов.* — к. перевить.

**ПЕРИВИВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. перевиться; 2. *страд.* яңадан ишелү (бау), яңадан үрелү.

**ПЕРЕВИ'ВКА** *ж.* — 1. яңадан үрү, яңадан ишү; *перевивка верёвки* — бауны яңадан ишү; *перевивка волос* — чәчне яңадан үрү; 2. *спец.* үрмә, үрелмә (үрелеп ясалган әйбер); *серебряная перевивка на черенке ножа* — пычак сабындагы көмеш үрелмә (яки үрмә).

**ПЕРЕВИВНО'Й** *спец.* — үрелмәле, үрелмә белән бизәлгән; *перевивной черенок ножа* — үрелмәле пычак сабы, үрелмә белән бизәлгән пычак сабы.

**ПЕРЕВИДА'ТЬ** *сов. разг.* — күпне күрү, күпне күреп бетерү; *много перевидал я на своём веку* — үз гомеремдә күпне күрдем мин.

**ПЕРЕВИНТИ'ТЬ** *сов.* — 1. (*заново ввинтить*) яңадан борып кую, яңадан борып кертү; 2. (*слишком туго завинтить*) артык каты бору; 3. *разг.* (*испортить, винтя*) артык каты борып бозу.

**ПЕРЕВИНТИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — артык каты борып бозылу.

**ПЕРЕВИ'НЧИВАТЬ** *несов.* — к. перевинтить.

**ПЕРЕВИ'НЧИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг.* к. перевинтиться; 2. *страд.* яңадан борып куелу.

**ПЕРЕВИРА'ТЬ** *несов. разг.* — к. переврать.

**ПЕРЕВИРА'ТЬСЯ** *несов. разг. страд.* — ялгыш әйтелү, бозып әйтелү.

**ПЕРЕВИСА'ТЬ** *несов. простореч.* — асылынып тору, салынып тору (берәр нәрсәгә).

**ПЕРЕВИСЕ'ТЬ** *сов. разг.* — артык озак эленеп тору; *бельё перевисело* — керләр артык озак эленеп торган.

**ПЕРЕВИ'СНУТЬ** *сов. простореч.* — асылынып төшү, салынып төшү (берәр нәрсә аркылы).

**ПЕРЕВИ'ТЬ** *сов.* — 1. яңадан ишү, яңадан үрү; *надо перевить слабо свитые верёвки* — йомшак (итеп) ишелгән бауларны яңадан ишәргә кирәк; 2. үреп кую; *она перевила косу лентой* — ул толымын тасма белән үреп куйды.

**ПЕРЕВИ'ТЬСЯ** *сов.* — уралып бетү, уралып үсү, чорналып үсү; *хмель перевился с малиной* — колмак кура җиләгенә уралып үскән.

**ПЕРЕВО'Д** *м.* — 1. күчерү; *перевод на другую должность* — башка хезмәткә күчерү; 2. тәрҗемә; *правильный перевод* — дөрес тәрҗемә; 3. *спец.* перевод бланкы-

сы; *продажа марок и переводов* — маркалар һәм перевод бланкылары сату. ◇ **Почтовый перевод** — почта белән җибәрү, почта белән җибәрелгән акча. **Пустой перевод денег** — акчаны юкка әрәм-шәрәм итү. **Нет переводу** *разг.* — һәрвакыт бар, бетәсе юк, бетмәслек; *в Москве ведь нет невестам переводу* (*Грибоедов*) — Москвада житкән кызларның бетәсе юк.

**ПЕРЕВО'ДИНА** *ж. спец.* — өрлек, матча.

**ПЕРЕВОДИ'ТЬ** I *несов.* — к. перевести.

**ПЕРЕВОДИ'ТЬ** II *сов. разг.* — йөртү, йөртеп чыгу; *за месяц экскурсовод в музее переводил тысячу посетителей* — музейдагы экскурсовод бер ай эчендә меңләп кеше йөртеп чыкты.

**ПЕРЕВОДИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. перевестись; 2. *страд.* күчерелү (бер урыннан икенче урынга); 3. *страд.* тәрҗемә ителү.

**ПЕРЕВОДНО'Й** и **ПЕРЕВО'ДНЫЙ** — 1. акча җибәрү...-ы, акча күчерү...-ы; *переводный бланк почтовый* — почта белән акча җибәрү бланкысы; 2. тәрҗемә ителгән; *переводный роман* — тәрҗемә ителгән роман; 3. *спец.* күчермә; *переводные картинки* — күчермә картинкалар; 4. копировка...-ы; *переводная бумага* — копировка кәгазе.

**ПЕРЕВО'ДЧЕСКИЙ** — тәрҗемәче...-ы; *переводческий труд* — тәрҗемәче хезмәте.

**ПЕРЕВО'ДЧИК** *м.*, **ПЕРЕВО'ДЧИЦА** *ж.* — тәрҗемәче.

**ПЕРЕВО'З** *м.* — 1. (бер урыннан икенче урынга) ташу, күчерү; *перевоз товаров* — товарлар ташу (атта, машинада); *перевоз мебели* — мебель күчерү; 2. аркылы чыгару; *перевоз грузов через реку* — елга аркылы йөкләр чыгару; 3. перевоз (елга аркылы чыгу көймәсе яки пароходы); 4. елга аркылы чыгару урыны.

**ПЕРЕВОЗИ'ТЬ** I *несов.* — (бер урыннан икенче урынга) ташу.

**ПЕРЕВОЗИ'ТЬ** II *сов. разг.* — ташып бетерү.

**ПЕРЕВОЗИ'ТЬСЯ** I *несов.* — 1. *страд.* ташылу; *вещи перевозятся на телеге* — әйберләр арба белән ташыла; 2. күчү, күченү, күченеп китү (бер урыннан икенче урынга).

**ПЕРЕВОЗИ'ТЬСЯ** II *сов. простореч.* — аунап пычранып бетү.

**ПЕРЕВО'ЗКА** *ж.* — ташу, күчерү; *перевозка грузов* — йөкләр күчерү.

**ПЕРЕВО'ЗНИЧАТЬ** *несов. спец. обл.* — су аркылы чыгаручы булып хезмәт итү, перевозда эшләү, су аркылы чыгару эше белән шөгыльләнү.

**ПЕРЕВО'ЗНЫЙ** *спец.* — су аркылы чыгару...-ы; (йөкне, товарларны) күчерү...-ы; *перевозный пункт* — су аркылы чыгару пункты.

**ПЕРЕВО'ЗНЯ** *ж. обл.* — зур көймә, борам.

**ПЕРЕВО'ЗОЧНЫЙ** — күчерү...-ы, су аркылы чыгару...-ы; *перевозочные средства* — күчерү чаралары (бер урыннан икенче урынга).

**ПЕРЕВО'ЗЧИК** *м.*, **ПЕРЕВО'ЗЧИЦА** *ж.* — елга аркылы чыгаручы (перевозда, паромда).

**ПЕРЕВО'ЗЧИЦКИЙ, ПЕРЕВО'ЗЧИЧИЙ** — елга аркылы чыгаручы...-ы; *перевозчицкая лодка* — елга аркылы чыгаручы көймәсе.

**ПЕРЕВОЛА'КИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. переволочь.

**ПЕРЕВОЛА'КИВАТЬСЯ** *несов. простореч.* — 1. к. переволочься; 2. *страд.* өстерәп китерелү.

**ПЕРЕВОЛНОВА'ТЬ** *сов. разг.* — дулкынландыру, борчып бетерү; *переволновать всех друзей* — барлык дусларны борчып бетерү.

**ПЕРЕВОЛНОВА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — борчылып бетү, артык борчылу; *переволновалась, пока не получила письма* — хат алганчы, борчылып бетте.

**ПЕРЕВОЛО'К** *м.* и **ПЕРЕВОЛО'КА** *ж. обл.* — к. волок.

**ПЕРЕВОЛОЧИ'ТЬ** *сов. простореч.* — к. переволочь.

**ПЕРЕВОЛОЧИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — к. переволочься.

**ПЕРЕВОЛО'ЧЬ** *сов. простореч.* — өстерәп китерү, өстерәп кертү; *переволочь тяжёлый мешок из сарая в сени* — авыр капчыкны сарайдан чоланга өстерәп кертү.

**ПЕРЕВОЛО'ЧЬСЯ** *сов. простореч.* — өстерәлеп килү, көч-хәл белән килеп җитү (бер җирдән икенче җиргә — хәлсез, авыру кеше турында).

**ПЕРЕВООРУЖА'ТЬ** *несов.* — к. перевооружить.

**ПЕРЕВООРУЖА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. перевооружиться; 2. *страд.* яңа кораллар белән тәэмин ителү, яңадан коралландырылу; яңа җиһазлау чаралары белән тәэмин ителү.

**ПЕРЕВООРУЖЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — яңадан коралланy, яңа кораллар белән тәэмин ителү; яңадан коралландыру.

**ПЕРЕВООРУЖЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. артык коралланганлык; 2. тулысынча яңа кораллар (җиһазлар) белән тәэмин ителгәнлек.

**ПЕРЕВООРУЖИ'ТЬ** *сов.* — 1. яңа кораллар белән тәэмин итү, яңадан коралландыру; *перевооружить армию* — армияне яңа кораллар белән тәэмин итү, армияне яңадан коралландыру; 2. *перен.* яңадан коралландыру, яңадан җиһазландыру; *технически перевооружить промышленность* — промышленностьны техник яктан яңадан коралландыру.

**ПЕРЕВООРУЖИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. яңа кораллар белән тәэмин ителү; яңа кораллар белән коралланy; *армия перевооружилась* — армия яңа кораллар белән тәэмин ителде; 2. *перен.* яңадан коралланy, яңадан җиһазланy; *промышленность технически перевооружилась* — промышленность техник яктан яңадан кораллaнды; 3. *перен.* (*овладеть лучшими формами работы*) эшнең яңа формаларын (алдынгы методларын) үзләштерү.

**ПЕРЕВОПЛОТИ'ТЬ** *сов. книж.* — яңача гәүдәләндерү, яңа формада гәүдәләндерү, бүтән рәвешкә кертү, яңа формада үзгәртү.

**ПЕРЕВОПЛОТИ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — яңа-

ча гәүдәләнү, бүтән рәвешкә керү, яңа форма алу, үзгәрү.

**ПЕРЕВОПЛОЩА'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — яңача гәүдәләнергә сәләтлелек, яңа формага керә алучанлык.

**ПЕРЕВОПЛОЩА'ТЬ** *несов. книж.* — к. перевоплотить.

**ПЕРЕВОПЛОЩА'ТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. к. перевоплотиться; 2. *страд.* яңача гәүдәләндерелү, бүтән рәвешкә кертелү, яңа форма бирелү, үзгәртелү.

**ПЕРЕВОПЛОЩЕ'НИЕ** *ср. книж.* — 1. яңача гәүдәләндерү; 2. яңача гәүдәләндерелү.

**ПЕРЕВОРА'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. перевернуть 1, 4.

**ПЕРЕВОРА'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. перевернуться; 2. *страд.* әйләндереп куелу, йөзтүбән капландырылу, әйләндерелү.

**ПЕРЕВОРА'ШИВАТЬ** *несов. разг.* — к. переворошить.

**ПЕРЕВОРА'ШИВАТЬСЯ** *несов. разг. страд.* — тузгытып кабартылу, актарылу, актарып чуалтып бетерелү.

**ПЕРЕВОРО'Т** *м.* — 1. переворот; *государственный переворот* — дәүләт перевороты; *октябрьский переворот в 1917 г. ликвидировал в России власть буржуазии и установил диктатуру пролетариата* — 1917 елгы Октябрь перевороты Россиядә буржуазия властен юк итте һәм пролетариат диктатурасын урнаштырды; 2. зур алмашыну, кискен үзгәреш; *я пишу тебе в минуту решительного переворота в моём существовании* (*Тургенев*) — мин сиңа үземнең яшәешемдә булган зур алмашыну минутында язам; 3. *простореч.* и *спец.* әйләнеш, әйләнү; *самолёт делал мёртвые петли и перевороты* — самолёт үлем элмәге һәм әйләнешләр ясый иде.

**ПЕРЕВОРОТИ'ТЬ** *сов.* — 1. *простореч.* к. перевернуть 1; 2. *разг. фам.* астын-өскә китерү; *он переворотил все вещи* — ул барлык әйберләрнең астын-өскә китерде.

**ПЕРЕВОРОТИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — к. перевернуться.

**ПЕРЕВОРО'ЧАТЬ** *сов. разг.* — әйләндереп (астын-өскә китереп) бетерү, чуалтып бетерү.

**ПЕРЕВОРОШИ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. тузгытып кабарту, чачалап кабарту, кабартып чыгу (печәнне); 2. *перен.* искә төшереп бер-бер артлы күз алдына китерү (вакыйгаларны); 3. актарып чуалтып бетерү; *он переворошил все бумаги на столе* — ул өстәлдәге барлык кәгазьләрне актарып чуалтып бетерде.

**ПЕРЕВОСПИТА'ТЬ** *сов.* — яңадан тәрбияләү, яңача тәрбияләү.

**ПЕРЕВОСПИТА'ТЬСЯ** *сов.* — яңадан тәрбияләнү.

**ПЕРЕВОСПИ'ТЫВАТЬ** *несов.* — к. перевоспитать.

**ПЕРЕВОСПИ'ТЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. перевоспитаться.

**ПЕРЕВРА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. ялгыш әйтү, бозып сөйләү; *переврать фамилию* — фамилияне ялгыш әйтү; *переврать все факты* — барлык фактларны бозып сөйләү; 2. *простореч.* (*превзойти во вранье*) ялганлауда уздыру (кемнән дә булса).

**ПЕРЕВСКРЫ'ТИЕ** *ср. мед.* — икенче кат яру (мәетне).

**ПЕРЕВЫБИРА'ТЬ** *несов.* — к. перевыбрать.

**ПЕРЕВЫБИРА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — яңадан сайлану.

**ПЕРЕВЫ'БОРНЫЙ** — яңа сайлаулар...-ы; *перевыборная кампания* — яңа сайлаулар кампаниясе.

**ПЕРЕВЫ'БОРЫ** *ед.* нет — яңадан сайлау; икенче кат сайлау, кабат сайлау (мәсәлән, беренче сайлау дөрес булып чыкмаса); 2. *простореч.* сайлаулар; *перевыборы месткома* — месткомга сайлаулар.

**ПЕРЕВЫ'БРАТЬ** *сов.* — 1. яңадан сайлау, икенче кат сайлау; *перевыбрать депутатов* — депутатларны яңадан сайлау; 2. *простореч.* яңа сайлаулар үткәрү; *перевыбрать членов президиума* — президиум членнарына яңа сайлаулар үткәрү.

**ПЕРЕВЫПОЛНЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — арттырып үтәү, арттырып тутыру; *перевыполнение нормы* — норманы арттырып үтәү.

**ПЕРЕВЫ'ПОЛНИТЬ** *сов.* — арттырып үтәү; *перевыполнить план* — планны арттырып үтәү.

**ПЕРЕВЫПОЛНЯ'ТЬ** *несов.* — к. перевыполнить.

**ПЕРЕВЫПОЛНЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — арттырып үтәлү; *план перевыполняется* — план арттырып үтәлә.

**ПЕРЕВЬЮ'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. перевьючить.

**ПЕРЕВЬЮ'ЧИТЬ** *сов.* — 1. (дөя, ишәк кебек хайваннар аркасындагы) йөкне бушатып яңадан төяү; *перевьючить верблюдов* — дөяләрнең йөген бушатып яңадан төяү; 2. төяп бетерү (барысын да, дөяләргә); *перевьючить весь товар* — барлык товарны (дөяләргә) төяп бетерү.

**ПЕРЕВЯЗА'ТЬ** *сов.* — 1. бәйләү; *перевязать рану* — яраны бәйләү; 2. төреп бәйләп чыгу, бәйләп бетерү; *перевязать все вещи* — барлык әйберләрне төреп бәйләп чыгу; 3. икенче тапкыр бәйләү, яңадан бәйләү, сүтеп яңадан бәйләү, башка төрле итеп бәйләү; *перевязать шарф* — шарфны яңадан бәйләү; *перевязать чулок* — оекны башка төрле итеп бәйләү; 4. *спец.* беркетү, тоташтыру (бура бураганда бүрәнәләрне, кирпеч бина салганда кирпечләрне).

**ПЕРЕВЯЗА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. үз ярасын үзе бәйләү; *раненый сам перевязался* — яралы кеше үз ярасын үзе бәйләде; 2. үзен бәйләп бетерү; *он весь перевязался бинтом* — ул үзен бөтенләй бинт белән бәйләп бетергән.

**ПЕРЕВЯ'ЗКА** *ж.* — 1. к. перевязать; 2. *простореч.* бәйләвеч.

**ПЕРЕВЯ'ЗОЧНЫЙ** *мед.* — яра бәйләү... -ы; бәйләвеч...; *перевязочный пункт* — яра бәйләү пункты; *перевязочные материалы* — бәйләвеч материаллар.

**ПЕРЕВЯ'ЗЫВАТЬ** *несов.* — к. перевязать.

**ПЕРЕВЯ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. перевязаться.

**ПЕ'РЕВЯЗЬ** *ж.* — 1. җилкәгә асу тасмасы,

җилкәгә асу каешы (кылыч, сумка кебекләрдә); *перевязь для сабли* — кылычны җилкәгә асу каешы; 2. *поэт. устар.* к. перевязка 2.

**ПЕРЕВЯ'СЛО** *ср. с.-х.* — көлтә бавы.

**ПЕРЕГАДА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. (күп нәрсә турында) уйлап бетерү; *думал и гадал — перегадал обо всём* — уйладым һәм фараз иттем — күп нәрсә турында уйлап бетердем; 2. (*погадать вновь*) икенче тапкыр күрәзәлек итү, фал ачу, багу.

**ПЕРЕГА'ДИТЬ** *сов. простореч.* — пычратып бетерү, шакшылап бетерү, әшәкеләндереп бетерү.

**ПЕРЕГА'ДЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. перегадать.

**ПЕРЕГА'ЖИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. перегадить.

**ПЕРЕГА'Р** *м. мн.* нет, *простореч.* — аракы тәме яки исе (күп эчкәннән соң); *несёт перегаром* — аракы исе аңкып тора. ◇ **Навоз-перегар** — артык черегән тирес, черемә. **Железо-перегар** — артык кыздырып бозылган тимер.

**ПЕРЕГА'РНЫЙ** *разг.* — көек...-ы; *перегарный дух* — көек исе.

**ПЕРЕГАСИ'ТЬ** *сов. разг.* — сүндереп бетерү, сүндереп чыгу; *перегасить лампы в коридорах* — коридорлардагы лампаларны сүндереп чыгу.

**ПЕРЕГА'СНУТЬ** *сов. разг.* — сүнеп бетү (берсе артыннан берсе); *огни в домах перегасли* — өйләрдәге утлар (берсе артыннан берсе) сүнеп беттеләр.

**ПЕРЕГИ'Б** *м.* — 1. бөгү, бөкләү; *перегиб палки* — таякны бөгү; 2. бөкләнгән урын; *на перегибе корешок книги лопнул* — бөкләнгән урынында китапның корешогы ертылган; 3. *перен. неодобр.* бөгелеш, перегиб (берәр нәрсәдә чиктән узу, актык чиккә житү, арттырып җибәрү һәм шуның аркасында дөреслекне бозу, эшне бозу); *борьба с перегибами* — перегибләр белән көрәш. ◇ **Сгибаться в перегиб** *разг. устар.* — ялагайланып баш ию, тәлинкә тоту.

**ПЕРЕГИБА'ТЬ** *несов.* — к. перегнуть.

**ПЕРЕГИБА'ТЬСЯ** *несов.* — к. перегнуться.

**ПЕРЕГИ'БНУТЬ** *сов. разг.* — һәлак булып бетү, бик күп һәлак булу, бик күп кырылу.

**ПЕРЕГИ'БЩИК** *м. разг. неодобр.* — бөгелешләр ясаучы, перегиб ясаучы, политик ялгышлар эшләүче.

**ПЕРЕГЛА'ДИТЬ** *сов.* — 1. яңадан үтүкләү, икенче тапкыр үтүкләү, кабат үтүкләү; *перегладить плохо выглаженное бельё* — начар үтүкләнгән керне кабат үтүкләү; 2. үтүкләп чыгу, үтүкләп бетерү; *перегладить всё бельё* — бөтен керне үтүкләп чыгу.

**ПЕРЕГЛА'ДЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. переглодать.

**ПЕРЕГЛА'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. перегладить.

**ПЕРЕГЛА'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — яңадан үтүкләнү.

**ПЕРЕГЛОДА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. кимереп бетерү; *собака переглодала все кости* — эт барлык сөякләрне кимереп бетерде; 2. кимереп өзү, чәйнәп өзү; *собака переглодала верёвку* — эт бауны чәйнәп өзгән.

**ПЕРЕГЛОТА'ТЬ** *сов. разг.* — йотып бетерү; ашап бетерү; *рыба переглотала всю приманку* — балык барлык җимне йотып бетергән (ашап бетергән).

**ПЕРЕГЛО'ХНУТЬ** *сов. разг.* — саңгыраулaнып бетү, чукракланып бетү; *все переглохли от канонады* — канонада тавышыннан барысы да чукракланып беттеләр.

**ПЕРЕГЛУШИ'ТЬ** *сов.* — 1. миңрәтеп үтереп бетерү, миңрәтеп кырып бетерү; *переглушили всю рыбу в пруду* — буадагы барлык балыкны миңрәтеп үтереп бетергәннәр; 2. *разг.* колакларын тондырып бетерү (күпнең, барысының да).

**ПЕРЕГЛЯДЕ'ТЬ** *сов. разг.* — карап чыгу; *переглядел все картины на выставке* — күргәзмәдәге барлык картиналарны карап чыкты.

**ПЕРЕГЛЯ'ДЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. переглядеть.

**ПЕРЕГЛЯ'ДЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. переглянуться.

**ПЕРЕГЛЯНУ'ТЬ** *сов. простореч.* — (берәр нәрсә аша) карау; *переглянул через забор* — койма аша карады.

**ПЕРЕГЛЯНУ'ТЬСЯ** *сов.* — карашып алу; күз салышып алу; *переглянулись и сразу поняли друг друга* — бер карашып алдылар да бер-берсен бик тиз аңладылар.

**ПЕРЕГНА'ИВАТЬ** *несов.* — к. перегноить.

**ПЕРЕГНА'ИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — черетеп бетерелү.

**ПЕРЕГНА'ТЬ** *сов.* — 1. узып китү; *он перегнал его* — ул аны узып китте; 2. куу, куып илтү, куып күчерү; *коров перегнали на другой луг* — сыерларны икенче болынга куып илттеләр; 3. *тех.* куу, состав кисәкләренә аеру; *перегнать нефть* — нефтьне куу (состав кисәкләренә аеру).

**ПЕРЕГНИВА'ТЬ** *несов.* — к. перегнить.

**ПЕРЕГНИ'ТЬ** *сов.* — череп бетү, черемәгә әйләнеп бетү.

**ПЕРЕГНОИ'ТЬ** *сов.* — черетеп бетерү; *перегноить сено* — печәнне черетеп бетерү.

**ПЕРЕГНО'Й** *м. мн.* нет — 1. черемә (туфракның үсемлек һәм хайван калдыкларыннан торган бер өлеше); 2. *обл.* черегән тирес.

**ПЕРЕГНО'ЙНЫЙ** *с.-х.* — черемәле; *перегнойная почва* — черемәле туфрак.

**ПЕРЕГНУ'ТЬ** *сов.* — 1. бөгү, бөкләү (икегә); *перегнуть лист железа пополам* — калай табагын урталай бөгү (бөкләү); 2. чамадан тыш бөгү. ◇ **Он перегнул в своих требованиях** — ул үзенең таләпләрендә бөтенләй арттырып җибәрде. **Перегнуть палку** *разг.* — арттырып җибәрү. **Перегнуть тело через перила** — култыксага салынып яту.

**ПЕРЕГНУ'ТЬСЯ** *сов.* — бик нык бөгелү, бик нык бөкләнү.

**ПЕРЕГОВА'РИВАТЬ** *несов.* — к. переговорить.

**ПЕРЕГОВА'РИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. (*обмениваться словами*) сөйләшеп алу; 2. *разг.* (*вести переговоры*) сөйләшүләр алып бару.

*передалась по наследственности* — авыру ана нәселдән күчкән; *кному скрипачу передалось от отца влечение к музыке* — музыкага булган дәрт яшь скрипачка атасыннан күчкән; 2. *разг. пренебр. устар.* бирелү; *передаться врагу* — дошманга бирелү, дошман ягына күчү.

**ПЕРЕДА'ЧА** *ж.*— 1. к. передать; 2. тапшыру; *слушать передачу по радио* — радио буенча тапшыруны тыңлау; 3. ашамлык, азык, передача; *принести передачу больному* — авыруга ашамлык (передача) китерү; 4. *тех.* тапшыргыч, передача; *зубчатая передача* — тешле тапшыргыч.

**ПЕРЕДБА'ННИК** *м. устар.*— к. предбанник.

**ПЕРЕДВА'ИВАТЬ** *несов.*— к. передвоить.

**ПЕРЕДВА'ИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. икенче кат сөрелү (җир); 2. икенче кат куылу (аракы, спирт).

**ПЕРЕДВИ'ГАТЬ** *сов. разг.*— күчереп бетерү; урыныннан күчереп бетерү, кузгатып бетерү; *всю мебель передвигал* — барлык мебельне урыныннан күчереп бетергән.

**ПЕРЕДВИГА'ТЬ** *несов.*— к. передвинуть.

**ПЕРЕДВИГА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. передвинуться; 2. йөрү; *больной с трудом передвигался* — авыру көчкә-көчкә генә йөри иде.

**ПЕРЕДВИЖЕ'НИЕ** *ср.*— 1. *только ед.* күчерү; *передвижение молодёжи в цехе с низшей работы на высшую* — цехта яшьләрне гади эштән югары эшкә күчерү; 2. күчү; *передвижение войск* — гаскәрләрнең күчүе.

**ПЕРЕДВИ'ЖКА** *ж. разг.*— 1. к. передвижение; 2. *разг.* күчмә культура-агарту учреждениесе; *библиотека-передвижка* — күчмә китапханә; *театр-передвижка* — күчмә театр.

**ПЕРЕДВИ'ЖНИК** *м. искус.*— передвижник (XIX йөзнең икенче яртысында яшәгән һәм „күчмә күргәзмәләр" дип йөртелгән күргәзмәдә катнашкан демократик художник-реалист); *Репин, Перов, Маковский, Суриков, Крамской являются крупнейшими из передвижников* — Репин, Перов, Маковский, Суриков, Крамской передвижникларның иң күренеклеләреннән саналалар.

**ПЕРЕДВИ'ЖНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *искус.*— передвижниклык (рус рәсем ясау сәнгатендә передвижниклар җитәкчелегендә булган реалистик юнәлеш).

**ПЕРЕДВИЖНО'Й** — 1. күчмә; *передвижная библиотека* — күчмә китапханә; *передвижной театр* — күчмә театр; *передвижная выставка* — күчмә күргәзмә; 2. күчерелмәле; *передвижной стол* — күчерелмәле өстәл.

**ПЕРЕДВИ'НУТЬ** *сов.*— 1. күчереп кую, күчерү; *передвинуть часовую стрелку* — сәгать телен күчереп кую; *передвинуть войска к границе* — гаскәрләрне ил чигенә күчерү; 2. *разг. перен.* кичектерү, күчерү; *передвинуть сроки выполнения работы* — эшне үтәү вакытын кичектерү.

**ПЕРЕДВИ'НУТЬСЯ** *сов.*— күчү; *стрелка часов передвинулась* — сәгать теле күчкән.

**ПЕРЕДВОИ'ТЬ** *сов.*— 1. *с.-х.* икенче кат сөрү (җирне); 2. *спец. обл.* икенче кат куу (аракыны, спиртны).

**ПЕРЕДЕ'Л** *м.*— 1. яңадан бүлү; 2. *истор. с.-х.* яңадан җир бүлү.

**ПЕРЕДЕ'ЛАТЬ** *сов.*— 1. яңадан эшләү, үзгәртеп эшләү, үзгәртеп ясау; *переделать платье* — күлмәкне үзгәртеп тегү; *переделать стихотворение* — шигырьне үзгәртеп язу; 2. үзгәртү; *переделать свой характер* — характерыңны үзгәртү; 3. *разг. простореч.* эшләп бетерү; *я все свои дела сегодня переделал* — бүген барлык эшләремне эшләп бетердем.

**ПЕРЕДЕ'ЛАТЬСЯ** *сов. разг.* — үзгәрү.

**ПЕРЕДЕЛИ'ТЬ** *сов.*— яңадан бүлү, икенче кат бүлү; *переделить земельный участок* — җир участогын яңадан бүлү.

**ПЕРЕДЕЛИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— яңадан бүлешү.

**ПЕРЕДЕ'ЛКА** *ж.*— к. переделать 1, 2. ◇ Попасть в переделку или побывать в переделке *разг.*— күп авырлыклар күрү, күпне кичерү, күпне күрү.

**ПЕРЕДЕ'ЛОЧНЫЙ** *спец.*— киемне үзгәртеп тегү...-ы; *переделочная мастерская* — киемне үзгәртеп тегү мастерское.

**ПЕРЕДЕ'ЛЫВАТЬ** *несов.*— к. переделать.

**ПЕРЕДЕ'ЛЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. *разг.* к. переделаться; 2. *страд.* яңадан эшләнү, үзгәртеп ясалу, яңадан ясалу.

**ПЕРЕДЕ'ЛЬНЫЙ** *спец.* — эшкәртү ...-ы, кабат эшкәртү ... ы; эшкәртелергә тиеш булган; *передельный чугун* — эшкәртеләсе чуен (корыч итеп эшкәртелергә тиеш булган чуен).

**ПЕРЕДЕЛЯ'ТЬ** *несов. разг.*— переделить.

**ПЕРЕДЕЛЯ'ТЬСЯ** *несов. разг.*— 1. к. переделиться; 2. *страд.* яңадан бүленү.

**ПЕРЕДЁРГАТЬ** *сов.*— йолкып бетерү, йолкып чыгу.

**ПЕРЕДЁРГИВАТЬ I** *несов.*— к. передёргать.

**ПЕРЕДЁРГИВАТЬ II** *несов.*— к. передёрнуть.

**ПЕРЕДЁРГИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— к. передёрнуться.

**ПЕРЕДЕРЖА'ТЬ** *сов.*— 1. артык тоту, тиешеннән озак тоту; *яйцо передержали в кипятке* — йомырканы кайнар суда артык тотканнар; 2. икенче тапкыр тоту; *передержать экзамен* — икенче тапкыр имтихан тоту; 3. *простореч.* (кулыннан) үткәрү; *много денег передержал кассир в своих руках* — кассир үз кулыннан күп акча үткәргән.

**ПЕРЕДЕРЖА'ТЬСЯ** *сов.*— артык тотылу, артык озак тотылу; *пластинки передержались в проявителе* — пластинкалар проявительдә артык тотылган.

**ПЕРЕДЕ'РЖИВАТЬ** *несов.*— к. передержать.

**ПЕРЕДЕ'РЖИВАТЬСЯ** *несов.*— к. передержаться.

**ПЕРЕДЕ'РЖКА I** *ж.*— 1. к. передержать; 2. *школьн. арго* икенче кат имтихан тоту;

*передержка осенью по математике* — көз көне математикадан икенче кат имтихан тоту.

**ПЕРЕДЕ'РЖКА II** *ж. разг.* — к. передёрнуть 2, 3.

**ПЕРЕДЁРНУТЬ** *сов.* — 1. тартып күчерү; *передёрнуть вожжи* — дилбегәне тартып (икенче якка) күчерү; 2. *(в карточный игре)* хәрәмләү; 3. *неодобр.* бозу, бозып китерү, бозып күрсәтү (ялгышны дөрес итеп күрсәтү өчен); *передёрнуть факты* — фактларны бозу, фактларны бозып күрсәтү; 4. *безл.* тән чымырдап китү; *меня передёрнуло от отвращения* — җирәнүдән тәнем чымырдап китте.

**ПЕРЕДЁРНУТЬСЯ** *сов. разг.* — чырае сытылу, тән чымырдап китү; *передёрнуться от страха* — куркудан тән чымырдап китү.

**ПЕРЕДИ'Р** *м мн.* нет, *с.-х.* — 1. к. передрать 4; 2. корпә.

**ПЕРЕДИРА'ТЬ** *несов.* — к. передрать.

**ПЕРЕДИРА'ТЬСЯ** *несов. разг. фам.* — 1. к. передраться; 2. *страд.* урталай ертылу, ертылып бетү.

**ПЕРЕДНЕВА'ТЬ** *сов. разг.* — көн үткәрү; бер көн үткәрү; *как рассвет, так лягу в лесу, переднюю, и ночью опять пойду (Л. Толстой)* — яктыру белән урманда ятып көн үткәрермен дә төнлә белән торып тагы китәрмен; *отряд передневал в ближайшей деревне* — отряд иң якындагы авылда көн үткәрде.

**ПЕРЕДНЕЯЗЫ'ЧНЫЙ** *лингв.* — тел алды..-ы; *переднеязычные гласные* — тел алды сузыклары (телнең алгы өлеше катнашы белән әйтелә торган сузыклар).

**ПЕРЕ'ДНИЙ** — ал, алгы; *передний фасад здания* — бинаның алгы ягы. ◇ **Передний угол** *обл.* — өй түре.

**ПЕРЕ'ДНИК** *м.* — 1. алъяпкыч; 2. *тех.* (кыру станогында) алгы такта.

**ПЕРЕ'ДНЯЯ** *ж.* — алгы бүлмә (өйдә, квартирада өске киемнәр саклана торган алгы бүлмә).

**ПЕРЕДО** *предлог* — к. перед II.

**ПЕРЕДОБЕ'ДЕННЫЙ** *разг.* — к. предобеденный.

**ПЕРЕДОБРИ'ТЬ** *сов. разг. фам. ирон.* — артык яхшылык күрсәтү, артык йомшаклык күрсәтү.

**ПЕРЕДОВА'Я** *ж.* — к. передовица.

**ПЕРЕДОВЕ'РИЕ** *ср. мн.* нет, *офиц.* — к. передоверить.

**ПЕРЕДОВЕ'РИТЬ** *сов. офиц.* — ышанып үзенә тапшырган эшне икенче берәүгә тап шыру.

**ПЕРЕДОВЕРЯ'ТЬ** *несов. офиц.* — к. передоверить.

**ПЕРЕДОВИ'К** *м.* — алдынгы; *передовики сельского хозяйства* — авыл хуҗалыгы алдынгылары; *передовики социалистического соревнования* — социалистик ярыш алдынгылары.

**ПЕРЕДОВИ'ЦА** *ж. разг.* — баш мәкалә (газета-журналларда).

**ПЕРЕДОВО'Й** — 1. алдынгы; *передовые колхозники* — алдынгы колхозчылар; 2. алдагы, алгы, алдан баручы; *передовая лошадь* — алдагы ат; *передовые позиции* — алгы позицияләр.

**ПЕРЕДОВЩИ'К** *м. обл.* — 1. алдан баручы, алдан җибәрелгән (кеше); 2. өлкән эшче (нинди дә булса артель эшендә).

**ПЕРЕДОИ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. кирәгеннән артык савып зарар китерү; *корову передоили, совсем зачахла* — сыерны кирәгеннән артык савып, бөтенләй ябыктырып бетергәннәр; 2. савып чыгу, савып бетерү; *передоила всех коров* — барлык сыерларны савып чыкты.

**ПЕРЕДО'К** *м.* — 1. арбаның алгы өлеше; 2. передок (снарядлар төяү һәм артиллерия орудиесен тагу өчен ике тәгәрмәчле арба).

**ПЕРЕДОКЛА'ДЫВАТЬ** *несов. офиц.* — к. передоложить.

**ПЕРЕДОКЛА'ДЫВАТЬСЯ** *несов. офиц. страд.* — яңадан белдерелү.

**ПЕРЕДОЛЖА'ТЬ** *сов. разг. фам.* — бурычка керү, бурычка бату.

**ПЕРЕДОЛОЖИ'ТЬ** *сов. канц.* — яңадан (кабат) белдерү (берәр эш турында).

**ПЕРЕДО'М** *нареч. простореч. обл.* — алда, алдан; *идти передом* — алдан бару.

**ПЕРЕДОПРА'ШИВАТЬ** *несов. офиц.* — к. передопросить.

**ПЕРЕДОПРА'ШИВАТЬСЯ** *несов. офиц. страд.* — икенче кат сорау алыну, кабат сорау алыну, яңадан җавап алыну.

**ПЕРЕДОПРО'С** *м. офиц.* — яңадан сорау алу (судта, тикшерү вакытында).

**ПЕРЕДОПРОСИ'ТЬ** *сов. офиц.* — икенче кат сорау алу, яңадан сорау алу.

**ПЕРЕДО'ХНУТЬ** *сов.* — үләп бетү, кырылып бетү (хайваннар турында).

**ПЕРЕДОХНУ'ТЬ** *сов. разг.* — иркенләп сулыш алу, бераз ял итеп алу, сулу алу, хәл җыю.

**ПЕРЕДРА'ЗНИВАТЬ** *несов.* — 1. үчекләү, үчекләп котырту; *ребята передразнивают друг друга* — балалар бер-берсен үчеклиләр; 2. кылану; *обезьяны передразнивают людей* — маймыллар кешечә кыланалар.

**ПЕРЕДРАЗНИ'ТЬ** *сов.* — к. передразнивать.

**ПЕРЕДРА'ТЬ** *сов.* — 1. *простореч. фам.* урталай ерту; 2. *разг. фам.* ертып бетерү, ерткалап бетерү (күпне, барысын да); 3. *разг. фам.* (күп кешене) дөмбәсләп ташлау, кыйнап ташлау; 4. ярдырып бетерү; 5. яңадан ярдыру, кабат ярдыру.

**ПЕРЕДРА'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.* — сугышып бетү, кыйнашып бетү; *ребята во дворе передрались* — йортта малайлар кыйнашып беткәннәр.

**ПЕРЕДРЕМА'ТЬ** *сов. разг. фам.* — йокымсырап алу (төнлә янсә билгеле бер вакытны)

**ПЕРЕДРО'ГНУТЬ** *сов. разг.* — туңып бетү, күшегеп бетү; *передрог на морозе* — салкында туңып беттем.

**ПЕРЕДРУЖИ'ТЬ** *сов. разг.* — дуслаштырып бетерү; *он не только помирил, но и передружил бывших соперников* — ул элекке көндәшләрне килештереп кенә калмады, ә дуслаштырып та бетерде.

**ПЕРЕДРУЖИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — дуслашып бетү (барысы белән дә, күбесе белән);

ләшеп чыгу (берникадәр кеше белән); *войдя, он перездоровался со всеми собравшимися* — кергәч ул җыелган кешеләрнең барысы белән дә исәнләшеп чыкты.

**ПЕРЕЗИМОВА'ТЬ** *сов.* — кышлау, кыш үткәрү, кыш чыгу; *перезимовать в деревне* — авылда кыш чыгу.

**ПЕРЕЗНАКА'МЛИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. перезнакомить.

**ПЕРЕЗНАКА'МЛИВАТЬСЯ** *несов. простореч.* — к. перезнакомиться.

**ПЕРЕЗНАКО'МИТЬ** *сов. разг.* — таныштырып чыгу; *он его перезнакомил со всеми гостями* — ул аны барлык кунаклар белән таныштырып чыкты.

**ПЕРЕЗНАКО'МИТЬСЯ** *сов. разг.* — танышып чыгу, танышып бетү.

**ПЕРЕЗО'Л** *м. мн.* нет, *тех.* — артык көлләү, артык селтеләү (кайбер материалларны эшкәрткәндә).

**ПЕРЕЗОЛИ'ТЬ** *сов. тех.* — чамадан тыш көлләп бозу, артык селтеләп бозу; *перезолить кожу* — тирене артык селтеләп бозу.

**ПЕРЕЗОЛИ'ТЬСЯ** *сов. тех.* — артык көлләнеп бозылу; артык селтеләнеп бозылу (тире турында).

**ПЕРЕЗОЛОТИ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. икенче кат алтынлау, яңадан алтынга ману, икенче кат алтын йөгертү; *перезолотить цепочку* — сәгать чылбырын яңадан алтынга ману; 2. алтынга манып чыгу, алтынга манып бетерү; *перезолотить все запонки* — барлык запонкаларны алтынга манып чыгу.

**ПЕРЕЗРЕВА'ТЬ** *несов.* — к. перезреть.

**ПЕРЕЗРЕ'ЛКА** *ж. разг. шутл. устар.* — карт кыз, утырып калган кыз, сазаган кыз.

**ПЕРЕЗРЕ'ЛОСТЬ** *ж. мн.* нет — үтә өлгергәнлек, үтә пешкәнлек, үтә җитлеккәнлек.

**ПЕРЕЗРЕ'ЛЫЙ** — 1. үтә пешкән, үтә өлгергән, үтә пешеп бозыла башлаган; *перезрелый арбуз* — үтә пешкән карбыз; 2. *перен. разг. фам.* сулган; *перезрелая красота* — сулган матурлык; 3. *перен. разг. фам.* яше узган, сазаган; *Анна Захаровна была перезрелая дева* — Анна Захаровна яше узган (сазаган) кыз иде.

**ПЕРЕЗРЕ'ТЬ** *сов.* — 1. үтә пешү, артык җитлегү, үтә өлгерү; үтә өлгереп бозыла башлау; *груши уже перезрели* — грушалар үтә пешкәннәр инде; 2. *перен. разг. шутл. ирон.* яше узу, картаю, картая төшү; *невеста перезрела* — кәләш буласы кыз картая төшкән.

**ПЕРЕЗЯ'БНУТЬ** *сов. разг.* — 1. туңып бетү, күшегеп бетү; *перезябла на морозе* — каты салкында туңып беттем; 2. өшеп бетү; *все цветы перезябли* — барлык чәчәкләр өшеп беткән.

**ПЕРЕИГРА'ТЬ** *сов.* — 1. икенче кат уйнау, кабат уйнау, яңадан уйнау; *переиграть пьесу на рояле* — пьесаны рояльдә яңадан уйнау; 2. артык уйнау, чамадан тыш уйнап җибәрү; *дети сегодня переиграли и потому долго не засыпают* — балалар бүген чамадан тыш уйнап җибәргәннәр, шуңа күрә озак йоклый алмый яталар; 3. уйнап чыгу, уйнап бетерү; *труппа переиграла весь свой репертуар* — труппа үзенең бөтен репертуарын уйнап чыкты; 4. *простореч.* (уйнауда) җиңеп чыгу; 5. *театр. арго* арттырып җибәрү (берәр рольне уйнауда); *он в этой роли переиграл* — ул бу рольне уйнаганда арттырып җибәрде.

**ПЕРЕИ'ГРЫВАТЬ** *несов.* — к. переиграть.

**ПЕРЕИ'ГРЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — икенче кат уйналу, яңадан уйналу, кабат уйналу.

**ПЕРЕИЗБИРА'ТЬ** *несов.* — к. переизбрать.

**ПЕРЕИЗБИРА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — яңадан сайлану.

**ПЕРЕИЗБРА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *офиц.* — к. переизбрать.

**ПЕРЕИЗБРА'ТЬ** *сов.* — яңадан сайлау, икенче кат сайлау; *переизбрать президиум* — президиумны яңадан сайлау.

**ПЕРЕИЗДАВА'ТЬ** *несов.* — к. переиздать.

**ПЕРЕИЗДАВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — яңадан басылу.

**ПЕРЕИЗДА'НИЕ** *ср.* — 1. к. переиздать; 2. кабат басма, яңадан басылган китап; *это не новая книга, а переиздание* — бу яңа китап түгел, кабат басма гына.

**ПЕРЕИЗДА'ТЬ** *сов.* — яңадан басу, кабат бастырып чыгару, яңадан бастыру, икенче кат бастыру; *переиздать учебник физики* — физика дәреслеген яңадан бастыру.

**ПЕРЕИМЕНОВА'НИЕ** *ср. книж.* — к. переименовать.

**ПЕРЕИМЕНОВА'ТЬ** *сов.* — яңа исем бирү, икенче исем бирү, исемен алмаштыру, икенче төрле исемләү; *переименовать улицу* — урамга икенче төрле исем бирү.

**ПЕРЕИМЕНОВА'ТЬСЯ** *сов.* — яңа исем бирелү, исеме алмаштырылу.

**ПЕРЕИМЕНО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. переименовать.

**ПЕРЕИМЕНО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. переименоваться.

**ПЕРЕИ'МКА** *ж. мн.* нет, *обл.* и *спец.* — к. перенять во 2, 3, 4 знач; *переимка плота на реке* — елгадагы салны тотып алу.

**ПЕРЕИ'МЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.* — үрнәк алучанлык, (чит кеше гадәтләрен) тиз үзләштерүчәнлек, тиз отып калучанлык.

**ПЕРЕИ'МЧИВЫЙ** *разг.* — башкалар гадәтен тиз үзләштерүчән, (чит кешедән) үрнәк алучан; *он переимчив на всякие выдумки* — ул төрле уйдырмаларны бик тиз үзләштерүчән.

**ПЕРЕИ'МЩИК** *м. разг.* — 1. (башкалардан) үрнәк алучан кеше, (башкалар гадәтен) тиз үзләштерүчән кеше; 2. тотып алучы, туктатучы (мәсәлән, елгада салны).

**ПЕРЕЙНА'ЧИВАТЬ** *несов. разг.* — к. переиначить.

**ПЕРЕИНА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. разг. страд.* — үзгәртелү, башка төрле эшләнү.

**ПЕРЕИНА'ЧИТЬ** *сов. разг.* — башка төрле эшләү, үзгәртү; *переиначить немного фразу, оставив прежний смысл* — элекке мәгънәсен калдырып, фразаны бераз үзгәртү.

**ПЕРЕИСКА'ТЬ** *сов. разг.* — эзләп чыгу, эзләп бетерү; *переискал всюду — не на*

*шёл* — бар җирдән эзләп чыктым — тапмадым.

**ПЕРЕИ'СКИВАТЬ** *несов. разг.* — 1. к. перерыскать; 2. яңадан эзләү, тагы бер кат эзләп чыгу; *ищи так, чтобы не переискивать (Даль)* — яңадан эзләмәслек итеп эзлә.

**ПЕРЕЙТИ'** *сов.* — 1. үтеп чыгу, аркылы чыгу; *войска перешли границу* — гаскәрләр чикне үтеп чыктылар; *перейти через мост* — күпер аркылы чыгу; 2. күчү; *перейти от одной картины к другой* — бер картинадан икенчегә күчү (күргәзмәдә); *перейти к очередным делам* — чираттагы эшләргә күчү; *войска перешли в наступление* — гаскәрләр һөҗүмгә күчтеләр; 3. *обл.* үтү, үтеп китү; *гроза перешла* — яшенле яңгыр үтеп китте; *время перешло за полночь* — ярты төн үтеп китте; 4. күчү, йогу; *болезнь от матери перешла к ребёнку* — авыру анадан балага йокты; 5. керү; *в русский язык перешёл много слов и выражений из французского* — француз теленнән рус теленә бик күп сүзләр һәм тәгъбирләр кергән; 6. чыгу; *либерал перешёл в лагерь консерваторов* — либерал консерваторлар лагерена чыкты. ◇ **Шопот перешёл в связную речь** *(Тургенев)* — пышылдау бәйләнешле сөйләмгә әйләнде. **Степь перешла в пустыню** — даладан соң чүл башланып китте. **Ссора перешла в драку** — кычкырыш кыйнашуга әйләнеп китте.

**ПЕРЕКА'Л** *м. мн.* нет, *тех.* — үтә кызганлык.

**ПЕРЕКАЛЕ'ЧИВАТЬ** *несов. разг.* — к. перекалечить.

**ПЕРЕКАЛЕ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — имгәтеп бетерелү, зәгыйфьләндереп бетерелү, гарипләндереп бетерелү.

**ПЕРЕКАЛЕ'ЧИТЬ** *сов. разг.* — имгәтеп бетерү, гарипләндереп бетерү.

**ПЕРЕКА'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. перекалить.

**ПЕРЕКА'ЛИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. перекалиться; 2. *страд.* чамадан тыш (артык) кыздырылу.

**ПЕРЕКАЛИ'ТЬ** *сов.* — 1. чамадан тыш (артык) кыздырып бозу; *перекалить железо* — тимерне чамадан тыш артык кыздырып бозу; 2. *разг.* артык кыздыру; *ты перекалила печь* — син мичне артык кыздыргансың.

**ПЕРЕКАЛИ'ТЬСЯ** *сов.* — артык кызу, артык кызып бозылу.

**ПЕРЕКА'ЛЫВАТЬ** *несов.* — к. переколоть.

**ПЕРЕКА'ЛЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг.* переколоться; 2. *страд.* күчереп кадап куелу.

**ПЕРЕКАЛЯ'КАТЬ** *сов. простореч. фам.* — бик күп лыгырдау, бик күп сөйләү, күп нәрсә турында лыгырдау.

**ПЕРЕКАЛЯ'ТЬ** *несов. разг.* — к. перекаливать.

**ПЕРЕКАЛЯ'ТЬСЯ** *несов. разг.* — к. перекаливаться.

**ПЕРЕКА'ПАТЬ** *сов. разг.* — 1. артык тамызып җибәрү; 2. тамчылап бушатып бетерү; *перекапать лекарство в другой пузырёк* — даруны бүтән шешәгә тамчылап бушатып бетерү.

**ПЕРЕКА'ПЧИВАТЬ** *несов. разг.* — к. перекоптить.

**ПЕРЕКА'ПЧИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. перекоптиться.

**ПЕРЕКА'ПЫВАТЬ** I *несов.* — к. перекопать.

**ПЕРЕКА'ПЫВАТЬ** II *несов. разг.* — к. перекапать.

**ПЕРЕКА'ПЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — яңадан казылу.

**ПЕРЕСКАЗА'ТЬ** *сов.* — **1.** сөйләп бирү, (үз сүзләрең белән) сөйләп чыгу; *пересказать содержание лекций* — лекцияләрнең эчтәлеген сөйләп бирү; **2.** *разг.* яңадан сөйләп бирү, икенче тапкыр сөйләп бирү; *пересказать сказку* — әкиятне яңадан сөйләп бирү; **3.** сөйләп чыгу, сөйләп бетерү, сөйләп бирү; *пересказать все новости* — барлык яңалыкларны сөйләп чыгу; **4.** *разг. фам.* (*сказать лишнее*) артык сөйләп җибәрү; **5.** *просторечь. устар.* (*насплетничать*) гайбәт сату, арттырып сөйләү. ◇ **Лучше не досказать, чем пересказать** — әйткәнең көмеш булса, тик торганың алтын; күп сүзнең азы яхшы, аз сүзнең үзе яхшы. **Скажешь с ноготок, перескажут с молоток** — берне биш итеп сөйлиләр.

**ПЕРЕСКА'ЗЧИК** *м.*, **ПЕРЕСКА'ЗЧИЦА** *ж. просторечь. устар.* — гайбәтче, сүз йөртүче.

**ПЕРЕСКА'ЗЫВАТЬ** *несов.* — к. пересказать.

**ПЕРЕСКА'ЗЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — сөйләп бирелү, яңадан сөйләнү, сөйләп чыгылу.

**ПЕРЕСКАКА'ТЬ** *сов. разг.* — **1.** (барысын да яки күбесен) чабып узып китү; **2.** *спорт. разг.* яңадан чабу; чабышны кабатлау; *перескакать ввиду неясного результата* — ачык нәтиҗә булмаганга яңадан чабу.

**ПЕРЕСКА'КИВАТЬ** *несов.* — **1.** к. перескочить; **2.** перескакать 1.

**ПЕРЕСКА'КНУТЬ** *сов. разг. фам.* — сикереп чыгу; *перескакнул через канаву* — канау аркылы сикереп чыкты.

**ПЕРЕСКОЧИ'ТЬ** *сов.* — **1.** сикереп чыгу; *перескочить через забор* — койма аркылы сикереп чыгу; **2.** *перен. разг.* калдырып үтү, сикертеп үтү; *он перескочил две скучные главы и опять погрузился в чтение* — ике күңелсез бүлекне калдырып үтте дә тагы да укырга керешге; **3.** *разг.* сикерү, сикереп күчү; *перескочил от окна к дивану* — тәрәзәдән диванга таба сикерде; **4.** *перен. разг. фам.* (эзлеклелек сакламыйча) кинәт күчү, сикерү; *он неожиданно перескочил к новой теме* — ул көтмәгәндә икенче темага күчте (сикерде).

**ПЕРЕСЛА'ИВАТЬ** *несов. спец.* — к. переслоить.

**ПЕРЕСЛА'ИВАТЬСЯ** *несов. спец.* — к. переслоиться.

**ПЕРЕСЛАСТИ'ТЬ** *сов. разг.* — артык балландыру, чамадан тыш шикәрләү, артык татлы итү (мәсәлән, чәйне, вареньены).

**ПЕРЕСЛА'ТЬ** *сов.* — җибәрү; салу; *переслать деньги по почте* — почта аша акча җибәрү.

**ПЕРЕСЛА'ЩИВАТЬ** *несов. разг.* — к. пересластить.

**ПЕРЕСЛА'ЩИВАТЬСЯ** *несов. разг. страд.* — артык балландырылу, чамадан тыш татлыландырылу.

**ПЕРЕСЛОИ'ТЬ** *сов. спец.* — катлап салу, катлау-катлау итеп аралаштырып салу, катлау-катлау аралаштырып өю; *переслоить песок с известью* — ком белән известьне катлам-катлам итеп аралаштырып өю.

**ПЕРЕСЛОИ'ТЬСЯ** *сов. спец.* — катлам-катлам булып аралашу; *песок переслоился с суглинком* — ком балчыклы туфрак белән катлам-катлам булып аралашкан.

**ПЕРЕСЛО'ЙКА** *ж. спец.* — **1.** *только ед. спец.* к. переслоить; **2.** *геол.* төрле тау токымнары катланмасы.

**ПЕРЕСЛУ'ЖИВАТЬ** *несов. разг.* — к. переслужить.

**ПЕРЕСЛУЖИ'ТЬ** *сов. разг.* — **1.** (тиешле сроктан) артыграк хезмәт итү; *переслужить лишний год в армии* — армиядә бер ел артыграк хезмәт итү; **2.** *фам.* хезмәт итеп чыгу, күп төрле хезмәттә булу; *на всех службах переслужил* — күп төрле хезмәттә булды (хезмәт итмәгән җире калмады).

**ПЕРЕСЛУ'ШАТЬ** *сов. разг.* — тыңлап бетерү, тыңлап чыгу; *всего не переслу-*

*шаешь* — барысын да тыңлап бетерә алмассын.

**ПЕРЕСЛУ'ШИВАТЬ** *несов. разг.* — к. переслушать.

**ПЕРЕСМА'ЛИВАТЬ** *несов. спец.* — к. пересмолить.

**ПЕРЕСМА'ЛИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг.* к. пересмолиться; 2. *страд. спец.* сумалалап чыгылу, яңадан сумалалану.

**ПЕРЕСМА'ТРИВАТЬ** *несов.* — к. пересмотреть.

**ПЕРЕСМА'ТРИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — икенче кат каралу; яңадан каралу; *дело пересматривается в областном суде* — эш өлкә судында яңадан карала.

**ПЕРЕСМЕ'ИВАТЬ** *несов. разг.* — шаярту, мыскыллап көлү (башка берәүдән).

**ПЕРЕСМЕ'ИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — көлешү (бер-береңә карап, берәр нәрсәдән, берәр кешедән).

**ПЕРЕСМЕХНУ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — көлешеп кую (бер-береңә карап, берәр нәрсәдән).

**ПЕРЕСМЕШИ'ТЬ** *сов. разг.* — көлдереп бетерү, көлдереп эчне катыру; *пересмешил нас своими рассказами* — үзенең сөйләүләре белән безне көлдереп бетерде.

**ПЕРЕСМЕ'ШКИ** *только мн. фам.* — мыскыллап көлү.

**ПЕРЕСМЕ'ШНИК** *м.*, **ПЕРЕСМЕ'ШНИЦА** *ж. разг. фам.* — мыскыллап көлүче, көлкегә калдыручы.

**ПЕРЕСМЕЯ'ТЬ** *сов. разг.* — к. пересмеивать.

**ПЕРЕСМОЛИ'ТЬ** *сов. спец.* — 1. яңадан сумалалау, икенче кат сумалалау (мәсәлән, көймәне); 2. сумалалап чыгу, сумалалап бетерү; *пересмолить все лодки* — барлык көймәләрне сумалалап чыгу.

**ПЕРЕСМОЛИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — сумалага пычранып бетү, сумалаланып бетү, сумалага буялып бетү.

**ПЕРЕСМО'ТР** *м.* — икенче кат карап чыгу, яңадан карап тикшерү; *пересмотр судебного дела* — суд эшен яңадан карап тикшерү; *рукопись возвращена автору для пересмотра* — кулъязма яңадан карап чыгу өчен авторына кайтарылды.

**ПЕРЕСМОТРЕ'ТЬ** *сов.* — 1. яңадан карап чыгу, икенче кат карап чыгу; *я пересмотрел все книги, но нужной не нашёл* — барлык китапларны яңадан карап чыктым, ләкин кирәклесен тапмадым; 2. яңадан тикшерү, яңадан карап тикшерү; *пересмотреть приговор* — суд хөкемен яңадан карап тикшерү; 3. *разг.* карап чыгу, күреп чыгу; *пересмотреть московские музеи* — Москва музейларын карап чыгу.

**ПЕРЕСНАРЯДИ'ТЬ** *сов. спец.* — кирәк-ярагын алмаштыру, кирәк-ярагын яңарту.

**ПЕРЕСНАРЯЖА'ТЬ** *несов. спец.* — к. переснарядить.

**ПЕРЕСНАРЯЖА'ТЬСЯ** *несов. спец. страд.* — кирәк-ярагы алмаштырылу, кирәк-ярагы яңартылу.

**ПЕРЕСНАСТИ'ТЬ** *сов. спец.* — судноны яңадан җиһазландыру, судноның кирәк-ярагын яңарту.

**ПЕРЕСНАЩА'ТЬ** *несов. спец.* — переснастить.

**ПЕРЕСНАЩА'ТЬСЯ** *несов. спец.* — к. переснащиваться.

**ПЕРЕСНА'ЩИВАТЬ** *несов. спец.* — к. переснастить.

**ПЕРЕСНА'ЩИВАТЬСЯ** *несов. спец. страд.* — яңадан җиһазландырылу, судноның кирәк-ярагы яңартылу.

**ПЕРЕСНИМА'ТЬ** *несов.* — к. переснять.

**ПЕРЕСНИМА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг.* к. пересняться; 2. *страд.* яңадан рәсемгә төшерелү.

**ПЕРЕСНЯ'ТЬ** *сов.* — 1. яңадан рәсемгә төшерү, яңадан рәсемен алу, кабат төшереп алу; *переснять кадр из фильма* — фильмның кадрын кабат төшереп алу; 2. *геодез.* (*сделать новую съёмку*) яңа съёмкасын эшләү.

**ПЕРЕСНЯ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — яңадан рәсемгә төшү.

**ПЕРЕСОВА'ТЬ** *сов. простореч.* — тыгып тутыру, ничек туры килсә, шулай тутыру (тәртипсез рәвештә төрле җиргә), тыккалап бетерү.

**ПЕРЕСОЗДАВА'ТЬ** *несов. книж.* — к. пересоздать.

**ПЕРЕСОЗДАВА'ТЬСЯ** *несов. книж. страд.* — яңадан булдырылу, яңадан барлыкка китерелү, яңача иҗат ителү, яңадан тудырылу.

**ПЕРЕСОЗДА'ТЬ** *сов. книж.* — яңадан булдыру, яңача барлыкка китерү, яңача иҗат итү, яңадан тудыру, үзгәртү, үзгәртеп кору.

**ПЕРЕСОЗИДА'ТЬ** *несов. книж.* — к. пересоздать.

**ПЕРЕСОЗИДА'ТЬСЯ** *несов. книж.* — к. пересоздаваться.

**ПЕРЕСО'Л** *м. мн.* нет — 1. артык тозлану, тозны артык салып җибәрү; 2. *перен. разг.* арттырып җибәрү; *пересол в шутках* — шаяртып сөйләүдә арттырып җибәрү.

**ПЕРЕСОЛЁНЫЙ** *разг.* — артык тозлы, артык тозланган.

**ПЕРЕСОЛИ'ТЬ** *сов.* — 1. артык тозлау, артык күп тоз салу; 2. тозлап чыгу, тозлап бетерү; *пересолить все грибы* — барлык гөмбәләрне тозлап бетерү; 3. *перен. разг. фам.* (*перейти какие-н. границы*) арттырып җибәрү, күпертеп җибәрү.

**ПЕРЕСОРТИРОВА'ТЬ** *сов. торг.* — 1. сортларга аерып чыгу, сортлап чыгу; 2. (*рассортировать заново*) яңадан сортларга аерып чыгу, икенче кат (башкача) сортлау.

**ПЕРЕСОРТИРО'ВЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. пересортировать.

**ПЕРЕСОРТИРО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. торг. страд.* — яңа сортларга аерылу, икенче кат сортларга аерып чыгылу.

**ПЕРЕСОСА'ТЬ** *сов.* — артык күп имү, чамадан тыш имү; *ребёнок пересосал* — бала артык күп имгән.

**ПЕРЕСО'ХЛЫЙ** *простореч.* — артык кип-

кән, кибеп беткән, бөтенләй кибеп беткән, артык коры.

**ПЕРЕСО'ХНУТЬ** *сов.*— 1. кибеп бетү, кибү; кирәгеннән артык кибү; *у меня губы пересохли* — иреннәрем кибеп бетте; 2. кору, корып бетү; *родник пересох* — чишмә корыган.

**ПЕРЕСОЧИНИ'ТЬ** *сов. разг.*— яңадан язу, башкача язу.

**ПЕРЕСОЧИНЯ'ТЬ** *несов. разг.*— к. пересочинить.

**ПЕРЕСОЧИНЯ'ТЬСЯ** *несов. разг.*— яңадан язылу, башкача язылу.

**ПЕРЕСПА'ТЬ** *сов.*— 1. (*проспать слишком долго*) артык озак йоклау, кирәгеннән артык йоклау; 2. *разг.* (башкалардан) озаграк йоклау; 3. *простореч.* төн үткәрү, кунып чыгу; *переспал у соседей* — күршеләрдә кунып чыктым.

**ПЕРЕСПЕВА'ТЬ** *несов. разг.*— к. переспеть.

**ПЕРЕСПЕ'ЛКА** *ж. обл.*— артык пешкән җиләк, артык пешкән җимеш.

**ПЕРЕСПЕ'ЛЫЙ** *разг.*— артык пешкән (җиләк-җимешләр, яшелчәләр турында).

**ПЕРЕСПЕ'ТЬ** *сов. разг.*— артык пешү (җиләк-җимешләр, яшелчәләр турында).

**ПЕРЕСПО'РИВАТЬ** *несов.*— к. переспорить.

**ПЕРЕСПО'РИТЬ** *сов.*— 1. бәхәстә җиңү, бәхәстә өстен чыгу; 2. *разг.* бәхәсләшеп ышандыру; *его не переспоришь, всё на своём стоит* — аны бәхәсләшеп ышандыра алмассың, ул һаман үзенекен итә.

**ПЕРЕСПРА'ШИВАТЬ** *несов.*— к. переспросить.

**ПЕРЕСПРА'ШИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— яңадан соралу.

**ПЕРЕСПРОСИ'ТЬ** *сов.*— 1. яңадан сорау, тагы бер кат сорау; 2. *разг.* (*спросить всех*) сорап чыгу, барысыннан да сорап бетерү.

**ПЕРЕССО'РИВАТЬ** *несов. разг.*— к. перессорить.

**ПЕРЕССО'РИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— к. перессориться.

**ПЕРЕССО'РИТЬ** *сов. разг.*— ызгыштырып бетерү, талаштырып бетерү, әрепләштереп бетерү.

**ПЕРЕССО'РИТЬСЯ** *сов. разг.*— ызгышып бетү, әрләшеп бетү, талашып бетү.

**ПЕРЕСТАВА'ТЬ** *несов.*— к. перестать.

**ПЕРЕСТА'ВИТЬ** *сов.*— күчереп кую, күчереп урнаштыру, урынын алмаштырып кую, (бер урыннан икенче урынга) күчереп кую; *переставить стол к окну* — өстәлне тәрәзә янына күчереп кую; *переставить всю мебель в комнате* — бүлмәдәге барлык мебельне күчереп кую. ◇ **Переставить часовых** — часовойларны алмаштыру, часовойлар куеп чыгу.

**ПЕРЕСТАВЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. переставить. ◇ **Еле ноги переставлять** *разг.*— көчкә-көчкә генә бару (атлау).

**ПЕРЕСТАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— күчереп куелу, күчереп урнаштырылу, урыны алмаштырылу.

**ПЕРЕСТАВНО'Й** *спец.*— күчереп куела торган, күчерелмә.

**ПЕРЕСТА'ИВАТЬ** *несов.*— к. перестоять.

**ПЕРЕСТА'ИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— к перестояться.

**ПЕРЕСТАНА'ВЛИВАТЬ** *несов. разг.*— к. переставлять.

**ПЕРЕСТАНА'ВЛИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— к. переставляться.

**ПЕРЕСТАНО'ВКА** *ж.*— 1. к. переставить; 2. үзгәреш; *в комнате полная перестановка* — бүлмәдә тулы үзгәреш; 3. *только мн. мат.* алмаштырмалар.

**ПЕРЕСТАРА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— артык тырышлык күрсәтү, урынсызга тырышлык күрсәтү.

**ПЕРЕСТА'РОК** *м. разг.*— картайган, картая төшкән, яше узган, яше чыккан.

**ПЕРЕСТА'ТЬ** *сов.*— туктау,...-мый башлау; *дождь перестал* — яңгыр туктады.

**ПЕРЕСТЕГА'ТЬ** I *сов. спец.*— 1. сырып чыгу, сырып бетерү; *перестегать все одеяла* — барлык юрганнарны сырып чыгу; 2. яңадан сыру; *перестегать одеяло* — юрганны яңадан сыру.

**ПЕРЕСТЕГА'ТЬ** II *сов. разг.*— камчылап чыгу, камчы белән сугып чыгу, чыбыркылап чыгу; *он перестегал всех лошадей* — барлык атларны камчылап чыкты.

**ПЕРЕСТЁГИВАТЬ** I *несов. спец.*— к. перестегать I.

**ПЕРЕСТЁГИВАТЬ** II *несов. разг.*— к. перестегать II.

**ПЕРЕСТЁГИВАТЬ** III *несов.*— к. перестегнуть.

**ПЕРЕСТЁГИВАТЬСЯ** *несов. спец. страд.*— яңадан сырылу.

**ПЕРЕСТЕГНУ'ТЬ** *сов.*— яңадан каптырып кую, яңадан төймәләп кую, башкача каптыру, икенче төрле төймәләү (сәдәпне, төймәне, каптырманы һ. б.).

**ПЕРЕСТЁЖКА** *ж. мн.* нет, *спец.*— яңадан сыру; сырып чыгу; *перестёжка одеял* — юрганнарны яңадан сыру.

**ПЕРЕСТЕЛИ'ТЬ** *сов. простореч.*— к. перестлать.

**ПЕРЕСТИЛА'ТЬ** *несов.*— к. перестлать.

**ПЕРЕСТИЛА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. яңача җәелү, яңадан түшәлү; 2. җәелеп бетү, түшәлеп бетү.

**ПЕРЕСТИРА'ТЬ** *сов.*— 1. яңадан юу, икенче кат уу, тагы бер кат юу (уу); 2. (*выстирать всё*) юып чыгу, юып бетерү.

**ПЕРЕСТИ'РЫВАТЬ** *несов.*— к. перестирать.

**ПЕРЕСТИ'РЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— яңадан юылу (уылу), тагы бер кат юылу (уылу).

**ПЕРЕСТЛА'ТЬ** *сов.*— 1. яңадан түшәү, яңадан җәю; 2. (*постлать всё, много*) түшәп чыгу, җәеп чыгу, түшәп бетерү, җәеп бетерү.

**ПЕРЕСТО'Й** *м. мн.* нет, *спец.*: **перестой хлебов** — игеннәрнең озак урмау сәбәпле коелуы; **перестой вина** — кызыл аракының озак торудан бозылуы.

**ПЕРЕСТОЯ'ТЬ** *сов.*— 1. кирәгеннән артык тору, артык торып коелу, артык торып бозылу; *простокваша перестояла* — әчегән сөт артык торып бозылган; 2. *разг.*

(берәр нәрсә узганны) көтеп тору; *перестоять бурю в порту* — портка кереп давыл узганны көтеп тору.

**ПЕРЕСТОЯ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — к. перестоять 1.

**ПЕРЕСТРА'ГИВАТЬ** *несов.* — к. перестрогать.

**ПЕРЕСТРА'ГИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — яңадан струклану, тагы бер кат ышкылану.

**ПЕРЕСТРАДА'ТЬ** *сов.* — күп газап чигү, күпне күрү, күпне кичерү, газапланып чыгу, җәфа чигеп чыгу, күп авырлыкны баштан үткәрү, авырлыклар кичерү.

**ПЕРЕСТРА'ИВАТЬ** *несов.* — к. перестроить.

**ПЕРЕСТРА'ИВАТЬСЯ** *несов.* — к. перестроиться.

**ПЕРЕСТРАХОВА'ТЬ** *сов.* — 1. яңадан страховать итү, икенче кат страховать итү (яки иттерү); 2. *разг.* страховать итеп (иттереп) чыгу; *перестраховать все дома* — барлык йортларны страховать итеп чыгу.

**ПЕРЕСТРАХОВА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. (гомереңне яки милкеңне) яңадан страховать итү; 2. *перен. неодобр.* җаваплылыкны үз өстеңнән алырга тырышу (төрле юллар белән).

**ПЕРЕСТРАХО'ВКА** *ж. мн.* нет — 1. к. перестраховать, перестраховаться; 2. *спец.* перестраховка (җаваплылыкның башка бер страховой учреждениегә йөкләнгән өлеше).

**ПЕРЕСТРАХО'ВЩИК** *м.*, **ПЕРЕСТРАХО'ВЩИЦА** *ж. неодобр.* — перестраховщик, перестраховщица; җаваплылыкны үз өстеннән төшерергә тырышучы.

**ПЕРЕСТРАХО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. перестраховать.

**ПЕРЕСТРАХО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг.* к. перестраховаться; 2. *страд.* яңадан страховать ителү.

**ПЕРЕСТРА'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. перестрочить.

**ПЕРЕСТРА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — яңадан каелу.

**ПЕРЕСТРЕ'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. перестрелять.

**ПЕРЕСТРЕ'ЛИВАТЬСЯ** *несов.* — атышу (утлы корал белән).

**ПЕРЕСТРЕ'ЛКА** *ж.* — атышу (утлы корал белән).

**ПЕРЕСТРЕЛЯ'ТЬ** *сов.* — 1. атып үтереп бетерү; 2. (*израсходовать всё стрельбой*) атып бетерү, атуга тотып бетерү (мәсәлән, патроннарны).

**ПЕРЕСТРЕЛЯ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — атышып үлү (күп кеше).

**ПЕРЕСТРИ'ГА** *ж. мн.* нет, *спец.* — икенче кат кыркып алынган йон; *перестрига мягче весенней шерсти* — икенче кат кыркып алынган йон язгы йоннан йомшаграк.

**ПЕРЕСТРИГА'ТЬ** *несов.* — к. перестричь.

**ПЕРЕСТРИГА'ТЬСЯ** *несов. разг.* — к. перестричься.

**ПЕРЕСТРИ'ЧЬ** *сов.* — 1. кыркып чыгу, йонын алып чыгу, йонын алып бетерү; *перестричь всех овец* — барлык сарыкларның йонын алу; 2. чәч алу, чәч кыскарту; *перестричь всех посетителей (в парикмахерской)* — (парикмахерскига килгән) барлык кешеләрнең чәчләрен алу.

**ПЕРЕСТРИ'ЧЬСЯ** *сов. разг.* — чәч алдыру; *все посетители перестриглись* — килүчеләрнең барысы да чәч алдырды.

**ПЕРЕСТРОГА'ТЬ** *сов.* — 1. (*выстрогать всё*) струклап чыгу, ышкылап чыгу, струклап бетерү; 2. (выстрогать заново) яңадан струклау, икенче кат струклау, яңадан ышкылау.

**ПЕРЕСТРОЕ'НИЕ** *ср. воен.* — 1. к. перестроить 2; 2. к. перестроиться 1.

**ПЕРЕСТРО'ИТЬ** *сов.* — 1. яңадан төзү, яңадан кору, үзгәртеп төзү, башкача төзү; 2. *перен.* башкача төзү, үзгәртү; *перестроить план* — планны башкача төзү; *перестроить предложение* — җөмләне башкача төзү; 3. *воен.* стройга башкача тезү, строен үзгәртү; *перестроить батальон* — батальонны стройга башкача тезү; 4. *муз.* башкача көйләү, яңартып көйләү (мәсәлән, балалайканы); 5. *радио* яңа дулкынга кую (радиоалгычны); 6. *разг.* (построить всё, много) төзеп чыгу, төзеп бетерү.

**ПЕРЕСТРО'ИТЬСЯ** *сов.* — 1. *воен.* стройны үзгәртү; *рота перестроилась на ходу* — рота юлда барганда строен үзгәртте; 2. *перен.* эшләү тәртибен үзгәртү; *необходимо перестроиться для лучшего выполнения задач строительства* — төзелеш бурычларын яхшырак үтәү өчен эшләү тәртибен үзгәртергә кирәк; 3. *радио* башка дулкынга куелу.

**ПЕРЕСТРОЧИ'ТЬ** *сов.* — 1. *порт.* (*выстрочить заново*) яңадан каю, яңадан каеп чыгу, башкача каю; 2. *порт.* (*выстрочить всё*) каеп бетерү, каеп чыгу; тегеп чыгу, тегеп бетерү; 3. *просторец. фам.* (*быстро переписать*) бик тиз генә күчереп язу.

**ПЕРЕСТУДИ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. (*остудить слишком*) артык суыту, чамадан тыш суыту; 2. суытып бетерү; *ты все комнаты перестудил* — син барлык бүлмәләрне суытып бетергәнсен.

**ПЕРЕСТУЖА'ТЬ** *несов. разг.* — к. перестудить.

**ПЕРЕСТУ'ЖИВАТЬ** *несов. разг.* — к. перестудить.

**ПЕРЕСТУ'КАТЬ** *сов. разг. фам. шутл.* — 1. ватып бетерү; *перестукали всю посуду* — барлык савыт-сабаны ватып бетергәннәр; 2. (язу машинкасында) басып алу.

**ПЕРЕСТУ'КИВАТЬ** *несов. разг. фам. шутл.* — к. перестукать 2.

**ПЕРЕСТУ'КИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. стена аркылы шакылдатып сөйләшү, аңлашу (төрмә камераларында); 2. *разг. фам.* телеграф аппараты аркылы сөйләшү.

**ПЕРЕСТУПА'ТЬ** *несов.* — 1. к. переступить; 2. атлап бару; *он еле переступал* — ул көчкә генә атлап бара иде; 3. әле бер аякны, әле икенче аякны күтәреп басып тору; алмаш-тилмәш аякларын күтәргәләп басып тору; *в конюшне переступали лошади, сочно хрустели травой* (Фадеев) — ат абзарында атлар әле бер аякларын, әле икенче аякларын күтәргәләп басып торалар һәм тәмләп печән ашыйлар иде.

**ПЕРЕСТУПИ'ТЬ** *сов.*—1. атлап аркылы чыгу; 2. *перен.* бозу; *переступить границы приличия* — әдәплелек нормаларын бозу, әдәпсез кылану; *переступить закон* — законны бозу.

**ПЕРЕСУ'Д** *м. простореч.*— икенче кат суд(та тикшерү).

**ПЕРЕСУ'ДЧИК** *м.*, **ПЕРЕСУ'ДЧИЦА** *ж. разг.*— гайбәтче, сүз йөртүче.

**ПЕРЕСУ'ДЫ** *разг. неодобр.*— гайбәт.

**ПЕРЕСУ'ЖИВАТЬ** *несов. разг.*— гайбәт сату.

**ПЕРЕСУ'НУТЬ** *сов. простореч.*— икенче бер җиргә илтеп тыгу.

**ПЕРЕСУ'ЧИВАТЬ** *несов. спец.*— к. пересучить.

**ПЕРЕСУ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— яңадан катылу.

**ПЕРЕСУЧИ'ТЬ** *сов. спец.*—1. (*ссучить снова*) яңадан кату (җеп турында); 2. (*ссучить всё*) катып бетерү (мәсәлән, җепне).

**ПЕРЕСУ'ШИВАТЬ** *несов.*— к. пересушить.

**ПЕРЕСУ'ШИВАТЬСЯ** *несов.*—1. к. пересушиться; 2. *страд.* артык киптерелү, чамадан тыш киптерелү.

**ПЕРЕСУШИ'ТЬ** *сов.*—1. артык киптерү, киптереп катырып бетерү; 2. (*высушить всё*) киптереп чыгу, киптереп бетерү.

**ПЕРЕСУШИ'ТЬСЯ** *сов.*—1. артык кибү, кибеп катып бетү; 2. (*высушиться*) кибеп бетү.

**ПЕРЕСЧИТА'ТЬ** *сов.*—1. санап чыгу, санап бетерү; 2. яңадан санап карау, яңадан санау. ◇ **Пересчитать кости или рёбра** *простореч. перен.*— кабыргасын санау (кыйнау).

**ПЕРЕСЧИ'ТЫВАТЬ** *несов.*—к. пересчитать.

**ПЕРЕСЧИ'ТЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— санап чыгылу, санап бетерелү, яңадан саналу, яңадан санап каралу.

**ПЕРЕСЪЁМЩИК** *м. спец.*— икенче кат съёмка ясаучы, икенче кат рәсемгә төшерүче.

**ПЕРЕСЫЛА'ТЬ** *несов.*— к. переслать.

**ПЕРЕСЫЛА'ТЬСЯ** *несов.*—1. *страд.* җибәрелү (икенче бер җиргә); 2. *разг.* хатлар алышу, посылкалар алышу.

**ПЕРЕСЫ'ЛОЧНЫЙ** *спец.*—(бер җирдән икенче җиргә) җибәрү...-ы, озату...-ы; *пересылочные операции*—(берәр нәрсәне) җибәрү операцияләре.

**ПЕРЕСЫ'ЛЬНЫЙ** *офиц.*— җибәрү...-ы, озату...-ы, озатып җибәрү...-ы; *пересыльный пункт* — озатып җибәрү пункты.

**ПЕРЕСЫ'П** *м. мн.* нет, *простореч. фам.*— артык йоклау; *голова с пересыпу болит* — артык йоклаудан баш авырта.

**ПЕРЕСЫ'ПАТЬ** *сов. разг.*—1. (икенче бер савытка) салу, тутыру, бушату; *пересыпать зерно в мешки* — ашлыкны капчыкларга тутыру (салу); 2. *разг.* артык салу, артык салып җибәрү; *пересыпать соли в суп* — ашка тозны артык салу; 3. араларына сибү; *пересыпать вещи в сундуке нафталином* — сандыктагы әйберләрнең араларына нафталин сибү. ◇ **Пересыпать** речь шутками — мәзәкләр кыстырып сөйләү.

**ПЕРЕСЫПА'ТЬ** I *несов.*— к. пересыпать.

**ПЕРЕСЫПА'ТЬ** II *несов.*— к. переспать.

**ПЕРЕСЫПА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— тутырылу, бушатылу (бер җирдән икенче җиргә).

**ПЕРЕСЫ'ТИТЬ** *сов. спец.*— чамадан тыш туендыру (мәсәлән, җирне дым белән).

**ПЕРЕСЫ'ТИТЬСЯ** *сов. спец.*— чамадан тыш туену (мәсәлән, җирнең су белән туенуы).

**ПЕРЕСЫХА'ТЬ** *несов.*— к. пересохнуть.

**ПЕРЕСЫЩА'ТЬ** *несов. спец.*— к. пересытить.

**ПЕРЕСЫЩА'ТЬСЯ** *несов. спец.*— к. пересытиться.

**ПЕРЕТА'ЛКИВАТЬ** *несов. разг.*— перетолкнуть.

**ПЕРЕТА'ЛКИВАТЬСЯ** *несов. разг. страд.*— этеп күчерелү.

**ПЕРЕТАНЦЕВА'ТЬ** *сов. разг.*—1. (*протанцевать всё*) танцевать итеп бетерү; (күп танцаларны) биеп чыгу; 2. (*заново протанцевать*) яңадан танцевать итү; башкача танцевать итү; 3. (*протанцевать лучше других*) яхшырак танцевать итү, озаграк танцевать итү.

**ПЕРЕТАНЦО'ВЫВАТЬ** *несов. разг.*— к. перетанцевать.

**ПЕРЕТА'ПЛИВАТЬ** *несов.*—к. перетопить I.

**ПЕРЕТА'ПЛИВАТЬСЯ** *несов.*—1. к. перетопиться I; 2. *страд.* яңадан эретелү.

**ПЕРЕТА'ПТЫВАТЬ** *несов.*— к. перетоптать.

**ПЕРЕТА'ПТЫВАТЬСЯ** *несов. простореч.*— таптанып тору.

**ПЕРЕТАСКА'ТЬ** *сов. разг.*—1. (бер җирдән икенче җиргә) ташып бетерү; *перетаскать все брёвна из сарая во двор* — барлык бүрәнәләрне сарайдан ишек алдына ташып бетерү; 2. *фам.* берәмләп урлап бетерү; 3. *простореч.* (бик күп кием) туздыру.

**ПЕРЕТА'СКИВАТЬ** *несов.*— к. перетаскать 1, 2.

**ПЕРЕТА'СКИВАТЬСЯ** *несов. разг. фам.*— к. перетащиться.

**ПЕРЕТАСОВА'ТЬ** *сов.*—1. болгату, тасовать итү (уен карталарын); 2. тагын бер кат болгату, яңадан болгату, аралаштыру (уен карталарын); 3. *перен.* (*перемешав, переместить*) урыннарын алмаштырып урнаштырып бетерү.

**ПЕРЕТАСО'ВЫВАТЬ** *несов.*— к. перетасовать.

**ПЕРЕТАСО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— болгатылу, яңадан болгатылу, аралаштырылу.

**ПЕРЕТАЧА'ТЬ** *сов. сапож. порт.*— яңадан каю, яңадан каеп чыгу.

**ПЕРЕТА'ЧИВАТЬ** I *несов. сапож. порт.*— к. перетачать.

**ПЕРЕТА'ЧИВАТЬ** II *несов.*— к. переточить.

**ПЕРЕТА'ЧИВАТЬСЯ** I *несов. страд. сапож. порт.*— яңадан каелу.

**ПЕРЕТА'ЧИВАТЬСЯ** II *несов. страд.*—

яңадан кайралу, яңадан чарлану, яңадан очлану.

**ПЕРЕТАЩИ'ТЬ** *сов.*—1. өстерәп (илтү) күчерү; тартып чыгару; *перетащить диван в соседнюю комнату* — диванны күрше бүлмәгә өстерәп күчерү; 2. *перен. разг. фам.* тарту (үз ягына), алу, алдыру; *перетащил его к себе в учреждение* — ул аны үз учреждениесенә алды.

**ПЕРЕТАЩИ'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.*— (бер җирдән икенче җиргә) көчкә-көчкә барып җитү.

**ПЕРЕТЕКА'ТЬ** *несов.*— к. перетечь.

**ПЕРЕТЕРЕ'ТЬ** *сов.*—1. ышкып өзү; *перетереть верёвку* — бауны ышкып өзү; 2. уу, кыру, кырып ваклау; *перетереть редьку на тёрке* — торманы кыргычта уу; 3. (*растереть ещё раз*) яңадан уу, яңадан кырып ваклау; 4. *простореч.* (*растереть слишком мелко*) артык вак итеп кыру (уу); 5. (*обтереть всё*) сөртеп бетерү, сөртеп чыгу (мәсәлән, савыт-сабаны). ◇ **Терпенье и труд всё перетрут** (*пословица*)— тырышкан табар — ташка кадак кагар.

**ПЕРЕТЕРЕ'ТЬСЯ** *сов.*— ышкылып өзелү (мәсәлән, бау).

**ПЕРЕТЕРПЕ'ТЬ** *сов. разг.*— бик күпне күрү, күпне баштан үткәрү, күпне баштан кичерү.

**ПЕРЕТЕРЯ'ТЬ** *сов. разг.*— югалтып бетерү.

**ПЕРЕТЕСА'ТЬ** *сов. спец.*—1. юнып чыгу, юнып бетерү; 2. яңадан юну, тагы бер кат юну.

**ПЕРЕТЁСЫВАТЬ** *несов. спец.*— к. перетесать.

**ПЕРЕТЁСЫВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— 1. яңадан юнылу; 2. юнып бетерелү.

**ПЕРЕТЕ'ЧЬ** *сов.*—1. (*перелиться куда-н.*) (бер җирдән икенче җиргә) агу; 2. (*перелиться через край*) ташып түгелү.

**ПЕРЕТИРА'ТЬ** *несов.*— к. перетереть.

**ПЕРЕТИРА'ТЬСЯ** *несов.*—1. к. перетереться; 2. *страд.* уылу, кырып ваклану.

**ПЕРЕТИ'СКАТЬ** *сов. простореч.*— кысып сытып бетерү, кысып чыгу, кысып таптап бетерү.

**ПЕРЕТИ'СКИВАТЬ** *несов. простореч.*— к. перетискать, перетиснуть.

**ПЕРЕТИ'СНУТЬ** *сов. простореч.*— яңадан басып алу (типографиядә).

**ПЕРЕТИХА'ТЬ** *несов. разг.*— к. перетихнуть.

**ПЕРЕТИ'ХНУТЬ** *сов. разг.*— басылып тору, басылу, басыла төшү; *ветер перетихнет на минутку и вновь задует с прежней силой* — җил әзрәк басылып тора да яңадан әүвәлгечә көчле исә башлый; *боль перетихла* — авырту басылды.

**ПЕРЕТКА'ТЬ** *сов. спец.*—1. бүтән төстәге аркау салып туку; 2. тукып чыгу, тукып бетерү (күпне, барысын да).

**ПЕРЕТКНУ'ТЬ** *сов. разг.*— икенче урынга кадап кую, башка җиргә чәнчеп кую.

**ПЕРЕТЛЕВА'ТЬ** *несов. разг.*— к. перетлеть.

**ПЕРЕТЛЕ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. череп бозылып бетү; 2. янып өзелеп чыгу, көйрәп өзелеп чыгу; *спичка перетлела пополам* — шырпы көйрәп өзелеп төште.

**ПЕРЕТОЛКА'ТЬ** *сов. простореч.*— этеп-төртеп бетерү.

**ПЕРЕТО'ЛКИ** *м. разг. фам.* — имеш-мимешләр, гайбәт, төрлечә борып сөйләүләр.

**ПЕРЕТОЛКНУ'ТЬ** *сов. разг.*— этеп күчерү, этеп кую.

**ПЕРЕТОЛКОВА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. киресен аңлатып бирү, киресен тугылау (сукалау); *он мои слова перетолковал по-своему* — ул минем сүзләрне үзенчә аңлатып биргән; 2. *простореч. фам. (переговорить о каком-н. деле)* сөйләшеп алу, аңлашып алу.

**ПЕРЕТОЛКО'ВЫВАТЬ** *несов. разг.*— к. перетолковать 1.

**ПЕРЕТОЛКО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. разг. страд.*— киресенчә аңлатылу, ялгыш аңлатылу.

**ПЕРЕТОЛО'ЧЬ** *сов.*— 1. төеп бетерү, төеп чыгу (барысын да); 2. *разг.* артык вак итеп төю; 3. *(истолочь снова)* яңадан төю, тагы бер кат төю.

**ПЕРЕТОЛО'ЧЬСЯ** *сов. разг.* — артык вак итеп төелү.

**ПЕРЕТОМИ'ТЬ** *сов.*— 1. *разг.* йөдәтеп бетерү, алҗытып бетерү, интектереп бетерү, талчыктырып бетерү, зарыктырып бетерү; 2. *спец. обл.* (парда яки берәр сыекчада тотып) йомшарту, җебетү; *перетомить кожу* — күнне йомшарту; 3. артык йомшарту, артык җебетү.

**ПЕРЕТОНЕ'ТЬ** *сов. простореч. обл.*— артык нечкәрү, артык юкару, чамадан тыш нечкә булып калу.

**ПЕРЕТОНИ'ТЬ** *сов. простореч.*— 1. *(сделать тоньше, чем нужно)* кирәгеннән артык нечкәртү (мәсәлән, тимер чыбыкны); 2. *перен. ирон.* хәйлә корып та максатына ирешмәү.

**ПЕРЕТОНЯ'ТЬ** *несов. простореч.* — к. перетонить.

**ПЕРЕТОПИ'ТЬ** I *сов.*— 1. *спец.* икенче кат эретү, икенче кат эретеп алу; *перетопить масло* — майны икенче кат эретеп алу; 2. эретеп бетерү; *перетопить всё сало* — барлык туң майны эретеп бетерү; 3. *разг.* ягып бетерү; ягып чыгу; *перетопить все печи* — барлык мичләрне ягып чыгу; *перетопить все дрова* — барлык утынны ягып бетерү; 4. *разг.* яңадан ягу, икенче кат ягу.

**ПЕРЕТОПИ'ТЬ** II *сов.*— батырып бетерү (барысын да).

**ПЕРЕТОПИ'ТЬСЯ** I *сов. спец.*— 1. эрү; *масло перетопилось* — май эреде; 2. яңадан эретелү, икенче кат эретелү.

**ПЕРЕТОПИ'ТЬСЯ** II *сов. разг. фам.*— батып үлеп бетү.

**ПЕРЕТО'ПКИ** *ед.* нет, *обл.*— турта, сызык.

**ПЕРЕТОПТА'ТЬ** *сов.*— 1. таптап бетерү; *перетоптать цветы* — чәчәкләрне таптап бетерү; 2. *спец.* аяк белән изү, аяк белән басу; *перетоптать глину* — балчыкны аяк белән изү.

**ПЕРЕТОРА'ЧИВАТЬ** *несов. спец.* — к. переторочить.

**ПЕРЕТОРА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. спец. страд.* — яңадан кайма тотылу.

**ПЕРЕТО'РЖКА** *ж. спец.* — яңадан торгига кую.

**ПЕРЕТОРМОШИ'ТЬ** *сов. разг.* — тарткалап йодәтеп бетерү, тарткалап алҗытып бетерү.

**ПЕРЕТОРОЧИ'ТЬ** *сов. спец.* — яңадан кайма тоту.

**ПЕРЕТОЧИ'ТЬ** *сов.* — **1.** үткенләп бетерү, очлап бетерү, кайрап бетерү; **2.** яңадан кайрау, яңадан очлау, икенче кат үткенләү; **3.** *разг.* артык үткенләп бозу, артык кайрап бозу.

**ПЕРЕТРАВИ'ТЬ** *сов.* — **1.** *охот.* аулап үтереп бетерү; **2.** агулап үтереп бетерү; *перетравить всех крыс* — барлык күселәрне агулап үтереп бетерү; **3.** *обл.* таптап әрәм итеп бетерү, эштән чыгару; *корова перетравила овощи на огороде* — сыер яшелчә бакчасындагы яшелчәләрне таптап эштән чыгарган; **4.** *простореч. неодобр.* ашатып әрәм итеп бетерү; *свиньям много хлеба перетравили* — дуңгызларга бик күп икмәк ашатып әрәм иткәннәр. ◇ **Перетравить всех собак на лису** — барлык этләрне төлкегә өстереп җибәрү. **Перетравить цинковую доску** — цинк тактаны кирәгеннән артык ашату, уйдыру.

**ПЕРЕТР'АВЛИВАТЬ** *несов.* — к. перетравить.

**ПЕРЕТРА'ГИВАТЬ** *несов.* — к. перетрогать.

**ПЕРЕТРА'ТИТЬ** *сов. разг.* — **1.** тотып бетерү; *все деньги на книги перетратил* — барлык акчамны китапларга тотып бетердем; **2.** артык тоту, артык туздыру (акчаны).

**ПЕРЕТРА'ЧИВАТЬ** *несов. разг.* — к. перетратить.

**ПЕРЕТРЕВО'ЖИТЬ** *сов. разг.* — **1.** *(причинить тревогу всем)* курку салу, борчып бетерү, тынычсызлап бетерү, аякка бастыру; **2.** *(очень встревожить)* бик нык борчу.

**ПЕРЕТРЕВО'ЖИТЬСЯ** *сов. разг.* — **1.** *(испытать тревогу)* куркуга төшү, тынычсызлану; **2.** бик нык борчылу; *все в доме перетревожились* — өйдәгеләр барысы да бик нык борчылдылар.

**ПЕРЕТРЕПА'ТЬ** *сов. простореч.* — **1.** киеп туздырып бетерү, киеп тетеп бетерү; **2.** талкып чыгу, тетеп чыгу, талкып бетерү, тетеп бетерү; *перетрепать весь лён* — барлык җитенне талкып чыгу.

**ПЕРЕТРЕ'СКАТЬСЯ** *сов. разг.* — **1.** ярылып бетү, ярграланып бетү; *глиняный горшок весь перетрескался* — балчык чүлмәк бөтенләй ярграланып беткән; **2.** чатнап бетү; *стаканы перетрескались* — стаканнар чатнап беткән.

**ПЕРЕТРО'ГАТЬ** *сов.* — кагылып чыгу, тиеп чыгу, тотып карап чыгу; *он все вещи перетрогал* — ул барлык әйберләрне тотып карады.

**ПЕРЕТРУДИ'ТЬ** *сов. разг.* — талдырып бетерү; *перетрудить руку* — кулны талдырып бетерү.

**ПЕРЕТРУДИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — артык күп эшләп ару, артык күп эшләп хәлсезләнү, артык эшләп хәлдән таю.

**ПЕРЕТРУЖДА'ТЬ** *несов. разг.* — к. перетрудить.

**ПЕРЕТРУ'СИТЬ** *сов. разг.* — бик нык курку, бик нык шүрләп калу.

**ПЕРЕТРУСИ'ТЬ** *сов. обл.* — **1.** *спец. (переворошить)* кабартып чыгу; *перетрусить сено* — печәнне кабартып чыгу; **2.** *(раструсить всё)* чәчеп-түгеп бетерү.

**ПЕРЕТРУ'СИТЬСЯ** *сов. обл.* — к. перетрусить.

**ПЕРЕТРУСИ'ТЬСЯ** *сов. обл.* — селкенә-селкенә чәчелеп (түгелеп) бетү.

**ПЕРЕТРУХНУ'ТЬ** *сов. разг. фам. ирон.* — бераз шүрләп калу, бераз куркып калу.

**ПЕРЕТРУ'ШИВАТЬ** *несов. обл.* — к. перетрусить.

**ПЕРЕТРЯСА'ТЬ** *несов.* — к. перетрясти.

**ПЕРЕТРЯСТИ'** *сов.* — **1.** селкеп тузанын кагу; *перетрясти всю одежду* — селкеп барлык киемнәрнең тузанын кагу; **2.** селкеп чыгу, селкеп карау; *перетрясти все вещи в поисках чего-нибудь* — берәр нәрсә эзләп барлык әйберләрне селкеп карау.

**ПЕРЕТРЯСТИ'СЬ** *сов. разг. фам.* — куркудан бик нык калтырану, куркып калтырану.

**ПЕРЕТРЯХА'ТЬ** *несов. простореч.* — к. перетряхнуть.

**ПЕРЕТРЯ'ХИВАТЬ** *несов.* — к. перетряхнуть.

**ПЕРЕТРЯ'ХИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — селкеп кабартылу.

**ПЕРЕТРЯХНУ'ТЬ** *сов.* — селкеп кабарту (мәсәлән, түшәкне).

**ПЕРЕТУПИ'ТЬ** *сов. разг.* — үтмәсләндереп бетерү; *перетупить все ножи* — барлык пычакларны үтмәсләндереп бетерү.

**ПЕРЕТУПИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — үтмәсләнеп бетү; *все ножи перетупились* — барлык пычаклар үтмәсләнеп беткән.

**ПЕРЕТУПЛЯ'ТЬ** *несов. разг.* — к. перетупить.

**ПЕРЕТУПЛЯ'ТЬСЯ** *несов. разг.* — к. перетупиться.

**ПЕРЕТЫ'КАТЬ** *сов. разг. фам.* — чәнчеп бетерү; кадап бетерү; *перетыкать все пальцы булавкой* — бөтен бармакларны булавка белән чәнчеп бетерү.

**ПЕРЕТЫКА'ТЬ** *несов. разг.* — к. перетнуть.

**ПЕРЕ'ТЬ** *несов. простореч.* — **1.** *вульг.* бару, элдертү; *прёт по самой грязи* — пычракны ярып бара, пычрактан элдертә генә; **2.** *неодобр. вульг.* этә-төртә бару; *прёт сквозь толпу* — халыкны этә-төртә бара; **3.** *(тащить какую-н. тяжесть)* сөйрәп яки күтәреп алып бару; **4.** *(красть) вульг.* урлау, чәлү. ◇ **Злоба так и прёт из него** — зәһәре йөзенә чәчрәп чыккан, ачуы йөзенә чыккан, ачуы йөзеннән күренеп тора.

**ПЕРЕ'ТЬСЯ** *несов. простореч. вульг.* — к. переть 1.

**ПЕРЕТЯГА'ТЬ** *сов.* — **1.** *простореч. обл.* аз-мазлап алып бетерү; аз-мазлап урлап бетерү; *перетягать всю мелочь из кошелька* — янчыктан бөтен вак акчаны аз-маз-

лап алып бетерү; 2. *устар.* өстен чыгу (судлашканда).

**ПЕРЕТЯ'ГИВАТЬ** *несов.*— к. перетянуть.

**ПЕРЕТЯ'ГИВАТЬСЯ** *несов.*— к. перетянуться.

**ПЕРЕТЯНУ'ТЬ** *сов.*— 1. тартып күчерү, тартып китерү, тартып илтү; *перетянуть лодку к берегу* — көймәне яр кырыена тартып китерү; 2. *тип.* (наборның бер өлешен икенче биткә) күчерү; 3. *перен. разг. фам.* (үз ягына) тарту, тартып алу; *перетянуть кого-н. на свою сторону* — берәр кешене үз ягына тарту; 4. артык кысып бәйләү; *перетянуть талию поясом*—билгә поясны артык кысып бәйләү; 5. авыррак тарту, баса төшү; *одна чашка весов перетянула* — үлчәүнең бер тәлинкәсе авыррак тартты; 6. (шинны) яңадан тарту (тарттыру); *перетянуть шины на колёсах* — көпчәкләрнең шиннарын яңадан тарту; 7. *разг.* тартып җиңү; *мы тянули за палку, и он перетянул* — без таяк тартышкан идек, ул тартып җиңде.

**ПЕРЕТЯНУ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. артык кысып бәйләү; *перетянуться поясом* — билбауны артык кысып бәйләү; 2. (борамда) тартылып чыгу.

**ПЕРЕУБЕДИ'ТЬ** *сов.*— фикерен үзгәртү, икенче бер фикергә күндерү; *трудно переубедить упрямого* — кире кешенең фикерен үзгәртү кыен.

**ПЕРЕУБЕДИ'ТЬСЯ** *сов.*— фикерне үзгәртү, карашны үзгәртү, икенче бер фикергә килү.

**ПЕРЕУБЕЖДА'ТЬ** *несов.* — к. переубедить.

**ПЕРЕУБЕЖДА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. переубедиться; 2. *страд.* фикере үзгәртелү, икенче бер фикергә китерелү.

**ПЕРЕУДИ'ТЬ** *сов. разг.*— (кармак белән) тотып бетерү; *переудить всю крупную рыбу из пруда* — буадагы барлык эре балыкны тотып бетерү.

**ПЕРЕУ'ЖИВАТЬ** *несов. разг.*— к. переудить.

**ПЕРЕУ'ЖИВАТЬСЯ** *несов. разг. страд.*— тотып бетерелү (балык).

**ПЕРЕУ'ЛОК** *м.*— тыкрык.

**ПЕРЕУ'ЛОЧНЫЙ** *разг.* — тыкрык...-ы; тыкрыктагы; *переулочная пыль* — тыкрык тузаны (тыкрыктагы тузан).

**ПЕРЕУПАКОВА'ТЬ** *сов.*— яңадан төреп бәйләү.

**ПЕРЕУПАКО'ВЫВАТЬ** *несов.*— к. переупаковать.

**ПЕРЕУПАКО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— яңадан төреп бәйләнү.

**ПЕРЕУПРЯ'МИТЬ** *сов. разг.*— киреләнеп җиңү, кирелектә уздыру; *меня не переупрямишь* — кирелектә миннән уздыра алмассың.

**ПЕРЕУСЕ'РДСТВОВАТЬ** *сов. разг. ирон.*— артык тырышлык күрсәтү, артык тырышу; *переусердствовать в похвалах* — артык тырышып мактау.

**ПЕРЕУСТРА'ИВАТЬ** *несов.* — к. переустроить.

**ПЕРЕУСТРА'ИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— башкача төзелү, башкача корылу, яңадан корылу, яңача корылу.

**ПЕРЕУСТРО'ИТЬ** *сов.* — башкача төзү, яңадан төзү, яңадан кору.

**ПЕРЕУСТРО'ЙСТВО** *ср. мн.* нет — яңача төзелеш, яңача корылыш, яңача төзү, үзгәртеп кору; *социалистическое переустройство общества* — җәмгыятьне социалистик нигездә яңача төзү.

**ПЕРЕУСТУПА'ТЬ** *несов. торг.*— к. переуступить.

**ПЕРЕУСТУПИ'ТЬ** *сов. торг.*— үз бәясенә сату, үз бәясенә бирү (элек сатып алынганны).

**ПЕРЕУТОМИ'ТЬ** *сов.*— ялыктырып бетерү, чамадан тыш арыту, артык йончыту.

**ПЕРЕУТОМИ'ТЬСЯ** *сов.* — чиктән тыш ялыгу, чамадан тыш ару, арып бетү.

**ПЕРЕУТОМЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — чиктән тыш ару, чамадан тыш ялыгу.

**ПЕРЕУТОМЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. переутомить.

**ПЕРЕУТОМЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— к. переутомиться.

**ПЕРЕУТЮ'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. переутюжить.

**ПЕРЕУТЮ'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— яңадан үтүкләнү.

**ПЕРЕУТЮ'ЖИТЬ** *сов.*—1. яңадан үтүкләү, икенче кат үтүкләү; 2. *(отутюжить всё, много)* үтүкләп чыгу, үтүкләп бетерү.

**ПЕРЕУЧЕ'СТЬ** *сов.*— яңадан санап чыгу, яңадан исәпкә алып чыгу, яңадан барлап чыгу.

**ПЕРЕУЧЁТ** *м. торг. фам.*— яңа учёт, яңадан барлау, икенче кат исәпкә алу.

**ПЕРЕУ'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. переучить.

**ПЕРЕУ'ЧИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. переучиться; 2. *страд.* яңадан укытылу; яңадан өйрәтелү.

**ПЕРЕУЧИ'ТЫВАТЬ** *несов.* — к. переучесть.

**ПЕРЕУЧИ'ТЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— яңадан исәпкә алыну, икенче кат учёт ясалу.

**ПЕРЕУЧИ'ТЬ** *сов.*— 1 *(обучить сызнова)* яңадан укыту, яңадан өйрәтү; 2.*(выучить снова)* яңадан өйрәнү; 3. *разг.* чамадан тыш артык укыту, артыграк укытып җибәрү; 4. укытып чыгу, укыту; *за свою долгую педагогическую деятельность он переучил сотни ребят* — үзенең күп еллык педагогик эшчәнлеге чорында ул йөзләрчә балалар укытты.

**ПЕРЕУЧИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. *(выучиться заново)* яңадан өйрәнү, башкача уку; 2. *разг.* артык күп укып үзенә зыян китерү.

**ПЕРЕФАСО'НИВАТЬ** *несов. порт. разг. фам.*— к. перефасонить.

**ПЕРЕФАСО'НИВАТЬСЯ** *несов. страд. порт. разг. фам.*— фасоны үзгәртелү, башка фасонда тегелү.

**ПЕРЕФАСО'НИТЬ** *сов.*— 1. *порт.* фасонын үзгәртү, башка төрле итеп тегү; 2. *перен. разг. фам.* үзгәртү, үзгәртеп төзү; *перефасонить статью* — мәкаләне үзгәртеп төзү (язу).

**ПЕРЕФОРМИРОВА'ТЬ** *сов. воен. офиц.*— үзгәртеп формировать итү, яңадан форми-

ровать итү; *переформировать дивизию* — дивизияне үзгәртеп формировать итү.

**ПЕРЕФОРМИРОВА'ТЬСЯ** *сов. воен. офиц.*— үзгәртеп формировать ителү, яңадан формировать ителү; *полк переформировался* — полк үзгәртеп формировать ителде.

**ПЕРЕФОРМИРО'ВЫВАТЬ** *несов. воен. офиц.*— к. переформировать.

**ПЕРЕФОРМИРО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд воен. офиц.*— к. переформироваться.

**ПЕРЕФРАЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.*— (берәүнең сүзләрен) бераз үзгәртү, үзгәртеп әйтү.

**ПЕРЕХВА'ЛИВАТЬ** *несов. разг.*— к. перехвалить.

**ПЕРЕХВАЛИ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. (*слишком расхвалить*) артык мактап җибәрү, кирәгеннән артык мактау; 2. (*всех, всё расхвалить*) мактап чыгу, мактап бетерү.

**ПЕРЕХВА'РЫВАТЬ** *несов. разг.*— к. перехворать.

**ПЕРЕХВАТА'ТЬ** *сов.*— 1. *разг.* кулга алып бетерү, тотып бетерү; 2. *простореч. вульг.* бик тиз алып бетерү, тиз арада сатып алып бетерү; *все нужные книги перехватали* — барлык кирәкле китапларны алып бетергәннәр; 3. *простореч.* (*захватать, повсюду потрогать*) капшап чыгу, тотып карап чыгу.

**ПЕРЕХВАТИ'ТЬ** *сов.*— 1. тотып алу, туктату (очып барганда, юлда); *перехватить мяч* — тупны тотып алу; *я перехватил его по дороге на службу* — мин аны хезмәткә барганда юлда туктаттым; 2. кулга төшерү, юлын кисү; *перехватить коммуникации противника* — дошманның коммуникацияләрен кулга төшерү (дошман армиясен базалары белән тоташтырган юлны кисү); 3. *охот.* (юлына аркылы барып) эзенә төшү; *перехватить след зверя* — җәнлекнең (юлына аркылы барып) эзенә төшү; 4. тотып алу, эләктереп алу; *я подержу бревно, а ты перехватишь его ниже* — мин бүрәнәне тотып торырмын, ә син астанрак эләктереп ал; 5. *разг.* кысып бәйләү, кысып бәйләп кую; *перехватить живот полотенцем* — эчне сөлге белән кысып бәйләп кую; 6. *разг. фам.* тиз генә ашап алу, тамак ялгап алу, капкалап алу; *перехватить что-н., чтоб червячка заморить* — йөрәк ялгау өчен берәр нәрсә капкалап алу; 7. *разг. фам.* кыска вакытка бурычка алу; *перехватить десять рублей* — кыска вакытка ун сум бурычка алу; 8. *простореч.* (*выхватить больше, чем нужно*) тиешеннән артык алу, артыграк алып җибәрү; 9. *разг. фам.* арттырып җибәрү; *это ты перехватил!*— бусын инде син арттырыбрак җибәрдең!

**ПЕРЕХВА'ТЫВАТЬ** *несов.*— к. перехватить, перехватать.

**ПЕРЕХВОРА'ТЬ** *сов. разг.*— 1. авырып чыгу; *все дети перехворали гриппом* — барлык балалар грипп белән авырып чыктылар; 2. күп авырулар белән авыру, күп авыру кичерү.

**ПЕРЕХИТРИ'ТЬ** *сов.*— 1. хәйләдә уздыру, хәйләдә өстен чыгу; 2. *разг. ирон.* артык хәйләкәрлек күрсәтеп эшне бозу, артык хәйләләп эшне бозу.

**ПЕРЕХИТРЯ'ТЬ** *несов.*— к. перехитрить.

**ПЕРЕХИХИ'КИВАТЬСЯ** *несов. разг. фам.*— хихылдашып бер-беренә күз кысышу.

**ПЕРЕХИХИ'КНУТЬСЯ** *сов. разг. фам.*— хихылдашып күз кысышып алу.

**ПЕРЕХЛЕСНУ'ТЬ** *сов.*— 1. (берәр нәрсә аркылы) чәчрәп керү, чәчрәп чыгу; *вода перехлеснула через борт* — су көймә кырые аркылы чәчрәп керде; 2. *перен. простореч. неодобр.* (*проявить излишнее усердие в чём-н.*) арттырып җибәрү, чыгырдан чыгу.

**ПЕРЕХЛЕСНУ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— к. перехлеснуть 1.

**ПЕРЕХЛЕСТА'ТЬ** *сов. простореч.*— чыбыркылап чыгу, суктырып чыгу.

**ПЕРЕХЛЁСТЫВАТЬ** I *несов.*— к. перехлеснуть.

**ПЕРЕХЛЁСТЫВАТЬ** II *несов. простореч.*— к. перехлестать.

**ПЕРЕХЛО'ПАТЬ** *сов.*— 1. *простореч.* (*слишком много похлопать*) озак кул чабу; 2. *разг.* кагып чыгу; *перехлопать всех по спине* — барысының да аркасыннан кагып чыгу. ◇ **Перехлопать мух** *разг.*— чебеннәрне сугып үтереп бетерү.

**ПЕРЕХЛО'ПЫВАТЬ** *несов.*— к. перехлопать.

**ПЕРЕХО'Д** *м.*— 1. кичү; *переход полководца Суворова через Альпы* — полководец Суворовның Альп таулары аркылы кичүе; 2. күчү, чыгу; *переход на сторону революционных войск* — революцион гаскәрләр ягына күчү; 3. басма; *устроить через реку два перехода* — елга аша ике басма салу; 4. *воен.* бер көнлек юл; *войска остановились в двух переходах от крепости* — гаскәрләр крепостьтан ике көнлек юлда туктадылар; 5. (ике бинаны бер-беренә тоташтыра торган) коридор, галерея.

**ПЕРЕХОДИ'ТЬ** I *несов.*— к. перейти.

**ПЕРЕХОДИ'ТЬ** II *сов.*— 1. *простореч.* йөреп чыгу; *все окрестности переходили* — барлык тирә-якны йөреп чыктылар; 2. *разг.* (шахмат, шашка уенында) ходны үзгәртү; икенче төрле йөрү.

**ПЕРЕХОДНО'Й** *простореч.*— к. переходный.

**ПЕРЕХО'ДНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— күчү, күчемлелек; *переходность глагола* — фигыльнең күчемлелеге.

**ПЕРЕХО'ДНЫЙ** 1. күчү...-ы; *переходный экзамен* — күчү экзамены; *переходная стадия* — күчү стадиясе; *переходный период* — күчү чоры; 2. *грам.* күчемле; *переходный глагол* — күчемле фигыль. ◇ **Переходный возраст** — күчү яше, аралык чоры (мәсәлән, балигъ булу).

**ПЕРЕХОДЯ'ЩИЙ** — 1. күчә торган; 2. күчмә; *переходящее красное знамя* — күчмә кызыл байрак; 3. *спец.* алмашынучан; *переходящие дожди* — алмашынучан яңгырлар; 4. *торг. фин. бухг.* күчә торган, күчерелмә (икенче елга күчерелә торган); *переходящие остатки* — күчерелмә калдыклар; *переходящие суммы* — күчерелмә суммалар.

**ПЕРЕХО'ЖИЙ: калики перехожие** — к. калика.

**ПЕРЕХОРОНИ'ТЬ** *сов.*— 1. (мәетне) күчереп күмү, күчереп җирләү; 2. (мәетләрне) күмеп бетерү.

**ПЕ'РЕЦ** *м. мн.* нет — 1. борыч; 2. *перен. разг. фам. шутл.* кызу канлы кеше, бәйләнчек кеше, сугыш чукмары. ◇ **Задать перцу** — к. задать.

**ПЕРЕЦАРА'ПАТЬ** *сов.*— тырнап бетерү, тырнатып бетерү; *перецарапал себе руки о колючую проволоку* — чәнечкеле тимер чыбыкка кулларымны тырнатып бетердем.

**ПЕРЕЦАРА'ПАТЬСЯ** *сов.*— 1. тырнашып бетү; *кошки перецарапались* — мәчеләр тырнашып беттеләр; 2. тырналып бетү; *перецарапался, перелезая через забор* — койма аркылы чыкканда тырналып беттем.

**ПЕРЕЦАРА'ПЫВАТЬ** *несов.*— к. перецарапать.

**ПЕРЕЦАРА'ПЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. перецарапаться; 2. *страд.* тырнап бетерелү.

**ПЕРЕЦЕДИ'ТЬ** *сов.*— 1. икенче кат сөзү, яңадан сөзү; 2. сөзеп агызу; *перецедить квас из бочки в ведро* — квасны мичкәдән чиләккә сөзеп агызу.

**ПЕРЕЦЕ'ЖИВАТЬ** *несов.*— к. перецедить.

**ПЕРЕЦЕ'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— икенче кат сөзелү, яңадан сөзелү.

**ПЕРЕЦЕЛОВА'ТЬ** *сов.*— үбеп чыгу; *перецеловал детей и поехал* — балаларны үбеп чыкты да китеп барды.

**ПЕРЕЦЕЛОВА'ТЬСЯ** *сов.*— үбешү, үбешеп чыгу; *все перецеловались перед отъездом* — китәр алдыннан барысы да үбештеләр.

**ПЕРЕЦЕ'НИВАТЬ** *несов. просторен.*— к. перецелить.

**ПЕРЕЦЕНИ'ТЬ** *сов. просторен.*— 1. *(оценить вновь)* яңадан бәяләү, яңа бәя билгеләү; 2. *(назначить слишком высокую цену)* артык зур бәя билгеләү, артыграк бәяләү.

**ПЕРЕЦЕПИ'ТЬ** *сов.*— 1. *спец.* яңадан тагу, башкача тагу; *перецепить вагоны* — вагоннарны башкача тагу; 2. *разг.* күчереп тагу; *перецепить значок с правого борта пиджака на левый* — значокны пиджакның уң ягыннан сул ягына күчереп тагу.

**ПЕРЕЦЕПЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. перецепить.

**ПЕРЕЦЕПЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— күчереп тагылу.

**ПЕРЕЧА'ЛИВАТЬ** *несов. спец.*— к. перечалить.

**ПЕРЕЧА'ЛИТЬ** *сов. спец.*— (көймәне, пароходны) бүтән урынга бәйләп кую.

**ПЕРЕЧА'ХНУТЬ** *сов. разг.*— корып (кибеп) бетү; шиңеп бетү; *все цветы перечахли* — барлык гөлләр корып (кибеп) беткән.

**ПЕРЕЧЕКА'НИВАТЬ** *несов. спец.*— к. перечеканить.

**ПЕРЕЧЕКА'НИВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— 1. яңадан сугылу, башкача сугылу (акча); 2. чүкеп яңадан (бизәк) ясалу, чүкеп ясалу, ясалып бетү (кубесе, барысы да).

**ПЕРЕЧЕКА'НИТЬ** *сов. спец.*— 1. *(вычеканить заново)* яңадан сугу (акчаны), чүкеп яңадан (бизәк) ясау; 2. *(выделать чеканкой всё)* чүкеп ясап бетерү.

**ПЕ'РЕЧЕНЬ** *м.*— исемлек; *перечень предметов широкого потребления* — киң куллану әйберләренең исемлеге.

**ПЕРЕЧЁРКАТЬ** и **ПЕРЕЧЕРКА'ТЬ** *сов. разг. фам.*— сызгалап бетерү, аркылы-торкылы сызып чыгу; *всю рукопись перечеркал* — бөтен кулъязманы сызгалап бетердем.

**ПЕРЕЧЁРКИВАТЬ** *несов.*— к. перечеркнуть, перечеркать.

**ПЕРЕЧЁРКИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— сызгалап бетерелү.

**ПЕРЕЧЕРКНУ'ТЬ** *сов.*— 1. (язылганны, басылганны) сызып ташлау, сызып бетерү; 2. *разг. (провести черту дальше, чем нужно)* озынрак сызу, тиешеннән арырак сызу.

**ПЕРЕЧЕРНИ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. *(сделать слишком чёрным)* артык каралту, артык каралап бетерү; 2. *(зачернить вторично)* икенче кат карага буяу; 3. *(зачернить всё)* карага буяп бетерү.

**ПЕРЕЧЕРНЯ'ТЬ** *несов. разг.*— к. перечернить.

**ПЕРЕЧЕ'РПАТЬ** *сов. разг.*— чумырып алып бетерү, сосып алып бетерү.

**ПЕРЕЧЕРПНУ'ТЬ** *сов. разг.*— артык күп итеп чумырып алу.

**ПЕРЕЧЕ'РПЫВАТЬ** *несов. разг.*— к. перечерпать, перечерпнуть.

**ПЕРЕЧЕ'РПЫВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— чумырып алып бетерелү, сосып алып бетерелү.

**ПЕРЕЧЕРСТВЕ'ЛЫЙ** *разг.*— искереп катып беткән (мәсәлән, икмәк).

**ПЕРЕЧЕРСТВЕ'ТЬ** *сов. разг.*— искереп катып бетү (мәсәлән, икмәк).

**ПЕРЕЧЕРТИ'ТЬ** *сов.*— 1. яңадан сызу, тагы бер кат сызу (мәсәлән, планны); 2. сызымның копиясен алу; 3. *разг.* сызып бетерү; *перечертить все чертежи за вечер* — бер кич эчендә барлык сызымнарны сызып бетерү.

**ПЕРЕЧЕ'РЧИВАТЬ** *несов.*— к. перечертить.

**ПЕРЕЧЕ'РЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. яңадан сызылу, тагы бер кат сызылу; 2. сызып бетерелү, сызып чыгылу; 3. сызымның копиясе алыну.

**ПЕРЕЧЕСА'ТЬ** *сов.*— 1. яңадан тарау, тагы бер кат тарау; *перечесать волосы* — чәчне яңадан тарау; 2. тарап бетерү, тарап чыгу; *перечесать всю шерсть* — барлык йонны тарап бетерү; *перечесать всех детей* — барлык балаларның чәчләрен тарап чыгу.

**ПЕРЕЧЕСА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— чәчне яңадан тарау (үз чәчеңне).

**ПЕРЕЧЕ'СТЬ** I *сов. разг.*— к. пересчитать.

**ПЕРЕЧЕ'СТЬ** II *сов. разг.*— к. перечитать.

**ПЕРЕЧЁСЫВАТЬ** *несов.*— к. перечесать.

**ПЕРЕЧЁСЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. *разг.* к. перечесаться; 2. *страд.* яңадан таралу (чәч).

**ПЕРЕЧИ'НИВАТЬ** *несов. разг.*— к. перечинить.

**ПЕРЕЧИНИ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. ямап чыгу, ямап бетерү; *перечинить бельё* — бельёны ямап бетерү; 2. очлап бетерү; *перечинить карандаши* — карандашларны очлап бетерү; 3. янадан ямау; *перечинить сорочку* — эчке күлмәкне янадан ямау; 4. яңадан очлау; *перечинить карандаш* — карандашны яңадан очлау.

**ПЕРЕЧИ'РКАТЬ** *сов. разг. фам.*— к. перечёркать, перечеркa'ть.

**ПЕРЕЧИСЛЕ'НИЕ** *ср.*— 1. *(действие)* санап чыгу, исемнәрен атап санап чыгу; 2. күчерү; *перечисление денег на текущий счёт* — агымдагы счётка акча күчерү; 3. *фин. бухг. (перечисленная сумма)* күчерелгән акча; 4. исемлек.

**ПЕРЕЧИ'СЛЕННЫЙ** — 1. күчерелгән; 2. саналган, санап чыгылган; исеме әйтелгән; *никто из перечисленных лиц не явился* — саналган кешеләрнең берсе дә килмәде.

**ПЕРЕЧИ'СЛИТЬ** *сов.*— 1. исемнәрен атап чыгу, исемнәрен атап санап чыгу; санап чыгу; *перечислить поимённо всех присутствующих* — мондагыларның барысын да исемнәрен атап санап чыгу; *перечислить прочитанные книги* — укылган китапларны атап санап чыгу; 2. *офиц.* күчерү; *его перечислили в хозяйственный отдел* — аны хуҗалык бүлегенә күчерделәр; *перечислить гонорар на текущий счёт в сберкассу* — гонорарны саклык кассасындагы агымдагы счётка күчерү.

**ПЕРЕЧИ'СЛИТЬСЯ** *сов. офиц. канц.*— күчү (икенче бер урынга, категориягә, хезмәткә).

**ПЕРЕЧИСЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. перечислить.

**ПЕРЕЧИСЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. *офиц. канц.* күчерелү; 2. атап санап чыгылу.

**ПЕРЕЧИ'СТИТЬ** *сов.*— 1. чистартып чыгу, тазартып чыгу, чистартып бетерү; 2. *(почистить вторично)* икенче кат чистарту (тазарту), тагы бер кат чистарту.

**ПЕРЕЧИТА'ТЬ** *сов.*— 1. янадан укып чыгу, тагы бер кат уку (хатны, китапны һ. б.); 2. укып чыгу, укып бетерү (күпне, барысын да); *перечитать все интересные книги в библиотеке* — китапханәдәге кызыклы китапларның барысын да укып чыгу.

**ПЕРЕЧИ'ТЫВАТЬ** *несов.*— кат-кат укып чыгу.

**ПЕРЕЧИ'ТЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— яңадан укылу, икенче кат укылу; укылып бетү.

**ПЕРЕ'ЧИТЬ** *несов.*— каршы әйтү, карулашу.

**ПЕРЕЧИЩА'ТЬ** *несов.*— к. перечистить.

**ПЕРЕЧИЩА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— яңадан чистартылу, икенче кат чистартылу (тазартылу).

**ПЕ'РЕЧНИЦА** *ж.*— борыч савыты. ◇ **Чортова перечница** *разг. вульг.*— убырлы карчык, җен карчыгы.

**ПЕ'РЕЧНЫЙ** — борыч...-ы; *перечный лист* — борыч яфрагы.

**ПЕРЕЧУ'ВСТВОВАТЬ** *сов.*— күпне хис итү; *что я перечувствовал в эту минуту — выразить невозможно* — ул минутта нәрсәләр хис иткәнемне сүз белән әйтеп булмый.

**ПЕРЕША'ГИВАТЬ** *несов.*— к. перешагнуть.

**ПЕРЕШАГНУ'ТЬ** *сов.*— 1. аркылы атлап чыгу; 2. *перен.* (законны, тыелганны, норманы) бозу.

**ПЕРЕША'РИВАТЬ** *несов. разг.*— к. перешарить.

**ПЕРЕША'РИТЬ** *сов. разг.*— актарып чыгу, актарып бетерү.

**ПЕРЕША'ТЫВАТЬСЯ** *несов. разг.*— алпан-тилпән килү; *идти, перешатываясь* — алпан-тилпән килеп бару.

**ПЕРЕШВЫ'РИВАТЬ** *несов. разг.*— к. перешвырять.

**ПЕРЕШВЫ'РИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— ыргытылу, ыргытып бетерелү.

**ПЕРЕШВЫРНУ'ТЬ** *сов. разг.*— ыргыту, ыргытып бетерү, ыргытып җибәрү; *перешвырнуть камень через забор* — ташны койма аркылы ыргытып җибәрү.

**ПЕРЕШВЫРЯ'ТЬ** *сов. разг.*— ыргытып бетерү.

**ПЕРЕШЕ'ЕК** *м. геогр.*— муен (зур су пространствосында ике коры җирне бергә тоташтырган тар коры җир).

**ПЕРЕШЁПТЫВАТЬСЯ** *несов.*— пышылдап сөйләшү.

**ПЕРЕШИБА'ТЬ** *несов. простореч.*— к. перешибить.

**ПЕРЕШИБА'ТЬСЯ** *несов. страд. простореч.*— сугып сындырылу, сугып өзелү.

**ПЕРЕШИБИ'ТЬ** *сов. простореч.*— сугып сындыру, сугып өзү. ◇ **Перешибить дорогу кому-нибудь** — кемнең дә булса юлына аркылы төшү (юлын кисү). **Плетью обуха не перешибёшь** — камчы белән балта түтәсен яра алмассың; чебен дулап тәрәзә вата алмас; тәкә сөзеп тау җимерелмәс.

**ПЕРЕШИВА'ТЬ** *несов.*— к. перешить.

**ПЕРЕШИВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. яңадан тегелү, яңача тегелү, башкача тегелү; 2. *плотн.* такталар ябып чыгылу.

**ПЕРЕШИ'ТЬ** *сов.*— 1. *(сшить по-другому)* яңадан тегү, төзәтеп тегү, яңача (башкача) тегү; 2. *плотн. (обшить заново досками)* яңадан такталар белән тышлап чыгу, яңадан обшивать итү; 3. *тех.* яңача беркетү, башкача беркетү, башка төрле итеп ясау, башка төрле итеп беркетү; *перешить рельсовый путь* — рельсларны башка төрле итеп беркетү; 4. *разг.* тегеп бетерү, тегеп чыгу (күпне, барысын да).

**ПЕРЕШЛИФОВА'ТЬ** *сов. спец.*— 1. яңадан шомарту, тагы бер кат шомарту; 2. шомартып чыгу, шомартып бетерү (күпне, барысын да).

**ПЕРЕШЛИФО'ВЫВАТЬ** *несов. спец.*— к. перешлифовать.

**ПЕРЕШЛИФО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. спец. страд.*— яңадан шомартылу, шомартып чыгылу.

**ПЕРЕШНУРОВА'ТЬ** *сов.*— 1. яңадан шнурлау, бүтәнчә шнурлау; 2. шнурлап чыгу, шнурлап бетерү (күпне, барысын да).

**ПЕРЕШНУРО'ВЫВАТЬ** *несов.*— к. перешнуровать.

**ПЕРЕШПИ'ЛИВАТЬ** *несов.*— к. перешпилить.

**ПЕРЕШПИ'ЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— күчереп кадап куелу, башка җиргә кадап куелу.

**ПЕРЕШПИ'ЛИТЬ** *сов.*— күчереп кадап кую, бүтән җиргә кадап кую (мәсәлән, булавканы).

**ПЕРЕШТЕМПЕЛЕВА'ТЬ** *сов.*— 1. штемпель басып чыгу; 2. икенче кат штемпель басу.

**ПЕРЕШТЕМПЕЛЁВЫВАТЬ** *несов.*— к. перештемпелевать.

**ПЕРЕШТО'ПАТЬ** *сов.*— 1. яңадан тупчу, төзәтеп тупчу; 2. тупчып чыгу, тупчып бетерү.

**ПЕРЕШТО'ПЫВАТЬ** *несов.*— к. перештопать.

**ПЕРЕШТО'ПЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— яңадан тупчылу.

**ПЕРЕШТУКАТУ'РИВАТЬ** *несов.*— к. перештукатурить.

**ПЕРЕШТУКАТУ'РИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — яңадан штукатурлану, тагы бер кат штукатурлану.

**ПЕРЕШТУКАТУ'РИТЬ** *сов.*— 1. яңадан штукатурлау, тагы бер кат штукатурлау; 2. штукатурлап чыгу, штукатурлап бетерү; *перештукатурить все стены* — барлык стеналарны штукатурлап чыгу.

**ПЕРЕЩЕГОЛЯ'ТЬ** *сов. разг.*— уздырып җибәрү, уздыру; *перещеголять кого.-н. в остроумии* — тапкыр сүзләр куллануда берәр кешедән уздыру.

**ПЕРЕЩЁЛКАТЬ** *сов. разг.*— 1. чиртеп чыгу; (барысына да, күбесенә); 2. ярып бетерү, шарт-шорт ватып бетерү (мәсәлән, чикләвекне).

**ПЕРЕЩЁЛКИВАТЬ** *несов. разг.*— к. перещёлкать.

**ПЕРЕЩИПА'ТЬ** *сов. разг.*— чеметеп чыгу; йолкып чыгу.

**ПЕРЕЩИ'ПЫВАТЬ** *несов.*— к. перещипать.

**ПЕРЕЩУ'ПАТЬ** *сов.*— капшап карап чыгу, капшап чыгу, тоткалап чыгу.

**ПЕРЕЩУ'ПЫВАТЬ** *несов.*— к. перещупать.

**ПЕРЕЭКЗАМЕНОВА'ТЬ** *сов. разг.*— 1. икенче кат имтихан алу, яңадан имтихан алу; 2. *(проэкзаменовать всех)* имтихан алып чыгу.

**ПЕРЕЭКЗАМЕНОВА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— икенче кат имтихан тоту, имтиханны яңадан тапшыру.

**ПЕРЕЭКЗАМЕНО'ВЫВАТЬ** *несов. разг.*— к. переэкзаменоватъ.

**ПЕРИГЕ'Й** *м. мн.* нет, *астр.*— перигей (Ай орбитасының Җиргә иң якын торган ноктасы).

**ПЕРИГЕ'ЛИЙ** *м. астр.*— перигелий (планета яки комета орбитасының Кояшка иң якын торган ноктасы).

**ПЕРИ'ЛА** *ед.* нет — култыкса, рәшәткә (күпер, баскыч яки балкон кырыенда була).

**ПЕРИ'ЛЬНЫЙ** *спец.*— култыкса...-ы; *перильная балясина* — култыкса текмәсе.

**ПЕРИ'ЛЬЧАТЫЙ** *спец.*— култыксалы.

**ПЕРИ'МЕТР** *м. мат.*— периметр (геометрик фигурада барлык кырларның озынлыклары суммасы); *периметр треугольника* — өчпочмак периметры.

**ПЕРИ'НА** *ж.*— ястык, түшәк (кош йоныннан яки мамыгыннан).

**ПЕРИ'ННЫЙ** — ястык...-ы, түшәк...-ы; *перинная холстина* — түшәк тышлыгы, түшәк тышлык киндер тукыма.

**ПЕРИ'ОД** *м. книж.*— 1. чор, вакыт, заман; *одесский период жизни Пушкина* — Пушкинның Одессада торган вакыты; *в течение долгого периода был учителем* — озак вакыт укытучы булып торды; *в период подготовки чего-нибудь* — берәр нәрсәне хәзерләү чорында (яки вакытында); *период военного коммунизма* — хәрби коммунизм чоры; *реконструктивный период* — реконструкция чоры; *инкубационный период болезни* — авыруның инкубация чоры; 2. *мат.* период; 3. *грам.* тезем (ритм белән төзелгән катлаулы гади яки зур кушма җөмлә); *простой период* — гади тезем; *сложный период* — катлаулы тезем.

**ПЕРИОДИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *книж. науч.*— чорларга бүлү; *периодизация всемирной истории* — бөтендөнья тарихын чорларга бүлү.

**ПЕРИО'ДИКА** *ж. мн.* нет, *собир. спец.*— вакытлы матбугат (газета-журналлар).

**ПЕРИОДИ'ЧЕСКИ** *нареч.* — 1. периодик рәвештә, вакыт-вакыт; *периодически повторяющиеся явления* — вакыт-вакыт кабатлана торган күренешләр; 2. *грам.* тезем рәвешендә; *речь построена периодически* — сөйләм тезем рәвешендә бирелгән.

**ПЕРИОДИ'ЧЕСКИЙ** *книж.*— 1. вакыт-вакыт кабатлана торган, периодик рәвештә кабатлана торган; *периодические кризисы — явление, неизбежное при капитализме* — периодик рәвештә кабатлана торган кризислар — капитализм чорында котылгысыз күренеш; 2. вакытлы; *периодическая печать* — вакытлы матбугат; 3. теземле, теземнәрдән торган; *периодическое построение речи* — теземнәрдән торган сөйләм; 4. *мат.* периодик; *периодическая десятичная дробь* — периодик унарлы вакланма.

**ПЕРИОДИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — периодик рәвештә булып тору, вакыт-вакыт булучанлык, вакыт-вакыт кабатланучанлык; *периодичность кризисов в капиталистическом обществе* — капиталистик җәмгыятьтә кризисларның периодик рәвештә булып торуы.

**ПЕРИОДИ'ЧНЫЙ** *книж.*— вакыт-вакыт кабатлана торган, вакыт-вакыт була торган.

**ПЕРИО'СТ** *м. анат.*— сөяк өслеге.

**ПЕРИОСТИ'Т** *м. мед.*— сөяк өслеге ялкынсыну.

**ПЕРИПЕТИ'Я** *ж. лит. театр.*— перипетия (роман, драматик әсәрләр геройларының язмышында, шулай ук кеше язмы-

шында кинәт үзгәреш, көтелмәгән кәтлаулылык).

**ПЕРИСКО'П** *м. спец.*— перископ (яшерен урыннан яки су асты көймәсеннән торып тирә-якны яки су өстен күзәтү приборы).

**ПЕРИСКОПИ'ЧЕСКИЕ СТЁКЛА** — перископик пыялалар (бер ягы кабарынкы, икенче ягы батынкы яки тигез итеп эшләнгән күзлек пыяласы).

**ПЕРИСТИ'ЛЬ** *м. архит.*— перистиль (бер яктан колонналар белән, икенче яктан бина стенасы белән чикләнгән өсте ябык галерея).

**ПЕРИСТОКРЫ'ЛЫЕ** *ср. зоол.*— каурыйсыман канатлылар (коңгызлар семьялыгыннан булган бөҗәкләр).

**ПЕРИСТОЛИ'СТНЫЙ** *бот.*— каурыйсыман яфраклы.

**ПЕ'РИСТЫЙ** — 1. *зоол.* каурыйлы; 2. *книж.* каурыйсыман, канатсыман; *перистые облака* — каурыйсыман болытлар; 3. *бот.* каурыйсыман яфраклы; *перистая пальма* — каурыйсыман яфраклы пальма.

**ПЕРИТОНИ'Т** *м. мн.* нет, *мед.*— перитонит (корсак ярысының ялкынсынуы).

**ПЕРИФЕРИ'ЙНЫЙ** — периферия...-ы; *периферийный работник* — периферия работнигы.

**ПЕРИФЕРИ'ЧЕСКИЙ** *науч.*— периферик; *периферическая нервная система* — периферик нервлар системасы.

**ПЕРИФЕРИ'Я** *ж. мн.* нет — 1. *мат.* периферия (түгәрәк әйләнәсе һәм гомумән фигураны чикли торган йомык кәкре сызык); 2. *перен. книж.* төп (асыл) булмаган яклар; *скользить по периферии чего-нибудь* — берәр нәрсәнең асылына төшенмичә эш итү; 3. *собир. офиц.* периферия, үзәктән читтәге өлкәләр; *работать на периферии* — периферийдә эшләү.

**ПЕРИФРА'З** *м.*, **ПЕРИФРА'ЗА** *ж. лит.* и *муз.*— к. парафраза.

**ПЕРЕФРАЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.*— к. парафразировать.

**ПЕРИФРАЗИ'РОВАТЬСЯ** *несов. книж.*— перифраза (парафраза) формасында бирелү.

**ПЕРИФРАСТИ'ЧЕСКИЙ** *книж.*— берничә сүз белән бирелгән; *перифрастические формы глагола* — фигыльнең берничә сүз белән бирелгән формалары (мәсәлән, барган иде).

**ПЁРКА** *ж. тех.*— пёрка (төрле формадагы бораулар).

**ПЕРКА'ЛЕВЫЙ** *спец.*— перкаль...; *перкалевая ткань* — перкаль тукыма.

**ПЕРКА'ЛЬ** *ж. разг. спец.*— перкаль (батистка охшаган юка киҗе-мамык тукыма).

**ПЕРКУ'ССИЯ** ж. *мн.* нет, *мед.*— перкуссия, каккалап карау (эчке органнарның хәлен тикшерү өчен бармаклар яки махсус кечкенә чүкеч белән кагып карау).

**ПЕРКУТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. мед.*— перкуссия ясау, каккалап карау.

**ПЕРЛ** *м.*— 1. *устар.* энҗе, энҗе бөртеге; 2. *перен. поэт.* энҗедәй саф; 3. *перен. книж.* энҗеләр, иң яхшысы, иң әйбәте, менә дигәне; 4. *тип.* бик вак хәрефләр.

**ПЕРЛАМУ'ТР** *м.*— перламутр (кабырчыкларның эчке катлавы).

**ПЕРЛАМУ'ТРОВЫЙ** — 1. перламутр...-ы; *перламутровый цвет* — перламутр төсе; 2. перламутр(дан ясалган); *перламутровая пуговица* — перламутр сәдәп.

**ПЕ'РЛИНЬ** *м. мор.*— перлинь (корабльдә махсус сүс аркан).

**ПЕРЛО'ВКА** *ж. мн.* нет, *простореч.*— арпа ярмасы.

**ПЕРЛО'ВЫЙ** — 1. арпа ярмасыннан пешерелгән; *перловая каша* — арпа ярмасыннан пешерелгән ботка; 2. арпа...-ы; *перловая крупа* — арпа ярмасы.

**ПЕРЛЮСТРАЦИО'ННЫЙ** *спец.*— (почтада) хатларны (яшерен) ачып уку...-ы; *перлюстрационный кабинет* — хатларны (яшерен) ачып уку кабинеты.

**ПЕРЛЮСТРА'ЦИЯ** *ж. спец.*— хатларны (яшерен) ачып уку (полиция тарафыннан); *царские жандармы подвергали перлюстрации корреспонденцию Пушкина* — патша жандармнары Пушкин хатларын яшерен ачып укый торган булганнар.

**ПЕРЛЮСТРИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. спец.*— яшертен ачып уку (хатларны).

**ПЕРЛЮСТРИ'РОВАТЬСЯ** *несов. спец. страд.*— яшертен ачып каралу (хатлар).

**ПЕРМАНЕ'НТ** *м.*— перманент (чәч бөдрәләтүнең бер төре).

**ПЕРМАНЕ'НТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— даимилек, өзлексезлек.

**ПЕРМАНЕ'НТНЫЙ** *книж.*— өзлексез, өзлексез дәвам итүче; даими; *перманентное развитие* — өзлексез үсеш.

**ПЕРМЯКИ'** *м.*— пермяклар (коми-пермякларның элекке атамасы; хәзерге вакытта Коми АССРның Коми-Пермяк милли округында яшиләр).

**ПЕРМЯ'ЦКИЙ** — пермяк...-ы; *пермяцкие селения* — пермяк авыллары.

**ПЕРМЯ'ЧКА** *ж.*— пермяк хатын-кызы.

**ПЕРНА'ТЫЕ** — кошлар.

**ПЕРНА'ТЫЙ** — 1. каурыйлы, канатлы; *пернатый царь лесных певцов* (соловей). (Пушкин) — урман сайраучыларының канатлы патшасы (сандугач); 2. *поэт. устар.* каурыйлы, канатлы, каурый белән бизәлгән; *пернатый шлем* — каурыйлы шлем.

**ПЕРО'** *ср.*— 1. каурый, йон (кош йоны); *очистить курицу от перьев* — тавыкның йонын йолку; *страусовые перья* — тәвә кошы каурыйлары; *набить подушку перьями* — мендәргә йон тутыру; 2. *охот.* кошлар, кош; *охотник по перу и пушнине* (Горький) — кошлар һәм җәнлекләр аулаучы; 3. каләм; *писать пером* — каләм белән язу; 4. *перен.* язу, язу сәләте, каләм; *у него перо бойкое* — аның каләме үткен; *взяться за перо* — яза башлау; 5. *охот.* эт койрыгы; *у породистого сеттера перо прямое или слегка выгнутое* — нәселле сеттерның койрыгы төз була яки әз генә өскә таба бөгелеп тора; 6. *(плавник)* балык канаты; 7. кыяк (суганда, сарымсакта); 8. *спец.* и *обл.* калак (сукада, ишкәктә һ. б.). ◇ **Что написано пером, того не вырубишь топо-**

**ром** — уйламый сөйләсән, авырмый үләрсең; әйткән сүз чыпчык түгел, очса тота алмассың; әйткән сүз — аткан ук; каләм белән язганны пәке белән кырып ташлый алмассың. **Ни пуха, ни пера** — хәерле юл, уңыш телим. **Казённые перья** *публиц. презрит.*— сатлык язучылар. **(Одним) росчерком пера** — бер сызу белән генә, уйлап-нитеп тормыйча (берәр нәрсә эшләү, юкка чыгару).

**ПЕРОЧИ'ННЫЙ**: **перочинный ножик** — карандаш очлый торган пәке.

**ПЕРПЕНДИКУЛЯ'Р** *м. мат.*— перпендикуляр.

**ПЕРПЕНДИКУЛЯ'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *мат.*— перпендикулярлык.

**ПЕРПЕНДИКУЛЯ'РНЫЙ** *мат.*— перпендикуляр...; *перпендикулярная линия* — перпендикуляр сызык.

**ПЕРПЕ'ТУУМ-МО'БИЛЕ** *нескл. м.* и *ср. книж.*— мәңгелек двигатель, мәңгелек хәрәкәт (физика законнарына каршы буларак куззаллана торган мәңгелек двигатель).

**ПЕРРО'Н** *м.*— **1.** *ж.-д.* перрон (вокзал платформасы); **2.** *архит.* (бина буенда) тәбәнәк таш терраса.

**ПЕРРО'ННЫЙ** — перрон...-ы; *перронный билет* — перрон билеты.

**ПЕ'РСИ** *ед.* нет — **1.** *книж. церк. поэт.* күкрәк; *бить себя в перси* — күкрәк кагу; **2.** *поэт.* хатын-кыз күкрәге.

**ПЕРСИ'ДСКИЙ** — фарсы...-ы; *персидский язык* — фарсы теле.

**ПЕ'РСИК** *м.*— **1.** шәфталу, шапталы (җимеш); **2.** *бот.* шәфталу агачы.

**ПЕ'РСИКОВЫЙ** — шәфталу...-ы; *персиковый вкус* — шәфталу тәме; *персиковое дерево* — шәфталу агачы; *персиковое варенье* — шәфталу вареньесы.

**ПЕРСИЯ'НИН** *м.*, **ПЕРСИЯ'НКА** *ж. устар.*— фарсы, иранлы.

**ПЕРСО'НА** *ж. книж.*— **1.** *торж.* или *ирон.* персона, кеше, зат; *сервиз на 12 персон* — унике кешелек сервиз; **2.** *устар.* или *ирон.* югары урындагы кеше, олы кеше. ◇ **Персона грата** *дипл.*— персона грата (берәр дәүләттә дипломатик вәкил итеп билгеләнүгә кандидатурасы куелган һәм шул дәүләтнең хөкүмәте тарафыннан шуңа ризалык алган кеше). **Собственной персоной** *торж. устар. теперь ирон.*— үзе, нәкъ үзе.

**ПЕРСОНА'Ж** *м.*— **1.** персонаж (драматик яки әдәби әсәрләрдә катнашучылар); **2.** шәхес, кеше; *комический персонаж* — көлке кеше.

**ПЕРСОНА'Л** *м. мн.* нет — персонал (учреждениенең, предприятиенең профессия яки башка берәр билгеләре буенча бер үк группага керә торган хезмәткәрләре; *технический персонал* — техник персонал; *учительский персонал* — укытучылар персоналы; *медицинский персонал* — медицина персоналы).

**ПЕРСОНАЛИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.*— гәүдәләндерү, (берәр) кеше образында бирү.

**ПЕРСОНАЛИЗИ'РОВАТЬСЯ** *несов. книж. страд.*— гәүдәләндерелү, берәр кеше образында бирелү.

**ПЕРСОНА'ЛЬНЫЙ** *книж. офиц.*— **1.** *устар.* персонал...-ы; *персональный состав* — персонал составы, берәр учреждениедә хезмәт итүчеләр составы; **2.** персональ, аерым кешегә багышланган, үзенә махсус билгеләнгән; *персональное приглашение* — персональ чакыру, үзенә аерым чакыру; *персональная пенсия* — персональ пенсия, үзенә аерым билгеләнгән пенсия.

**ПЕРСОНИФИКА'ЦИЯ** *ж. книж.*— (берәр предметны яки абстракт төшенчәне) кеше образында бирү, кеше образында гәүдәләндерү, персоналаштыру.

**ПЕРСОНИФИЦИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.*— кеше образында бирү, кеше образында гәүдәләндерү.

**ПЕРСОНИФИЦИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов.*— **1.** кеше образына керү, кеше образында гәүдәләнү; **2.** *страд.* кеше образында бирелү, кеше образында гәүдәләндерелү.

**ПЕРСПЕКТИ'ВА** *ж. книж.*— **1.** ерактан күренгән табигать картинасы, табигать күренеше; *в перспективе всё это имело другой вид* — ерактан караганда болар барысы да башка төрле күренә иде; *морская перспектива* — диңгез күренеше; **2.** *живоп.* перспектива, ерактан күренеш; *законы перспективы* — ерактан күренеш законнары; **3.** *устар.* (озын туры) урам, проспект; *Невская перспектива* — Невский проспект (Ленинградта хәзер 25 Октябрь проспекты); **4.** *перен.* перспектива, киләчәк; *политические перспективы Европы* — Европаның политик перспективалары. ◇ **В перспективе** — киләчәктә. **Хорошие перспективы на урожай** — уңышның яхшы булачагы күренә.

**ПЕРСПЕКТИ'ВНЫЙ** *книж.*— **1.** перспектив, киләчәктәге; *перспективный план развития хозяйства* — хуҗалык үсешенең перспектив планы; **2.** өметле, киләчәге өметле булган; *перспективные работы* — киләчәге өметле булган эшләр.

**ПЕРСТ** *м. книж. устар. ритор.* или *ирон.*— бармак, кул бармагы. ◇ **Перст судьбы** — язмыш күрсәтүе, тәкъдирдә язылганнар. **Один, как перст** — япа-ялгыз.

**ПЕРСТЕНЁК** *м. разг.*— кечкенә йөзек, нәфис йөзек.

**ПЕ'РСТЕНЬ** *м.*— йөзек.

**ПЕРСТНЕВИ'ДНЫЙ** *анат.*— йөзексыман; *перстневидный хрящ* — йөзексыман кимерчәк.

**ПЕРСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж. ритор. устар.*— **1.** тузан, туфрак; **2.** мәет, үле гәүдә.

**ПЕ'РСЫ** *м. устар.*— фарсылар, иранлар.

**ПЕРТУРБА'ЦИЯ** *ж. книж.*— **1.** *(внезапный переворот)* кинәт борылыш, буталыш, чуалыш, тәртипсезлек, асты өскә килү; **2.** *астр.* пертурбация (планетаның яки кометаның башка планеталарның тарту көчләре тәэсирендә үз юлыннан тайпылуы).

**ПЕРУА'НКА** *ж.*— перулы хатын-кыз.

**ПЕРУА'НСКИЙ** — **1.** перулылар...-ы; *пе-*

*руанский танец* — перулылар биюе; 2. Перу...-ы; *перуанское правительство* — Перу хөкүмәте.

ПЕРУА'НЦЫ — перулылар (Көньяк Америкада Перу республикасында яшәүче халык).

ПЕРУ'НЫ *книж. поэт. устар.* — перуннар (бәхетсезлек, бәла символы). ◇ **Метать перуны** *книж. ритор.* — ачулану, зәһәрләнү.

ПЕРФОРА'ТОР *м. тех.* — перфоратор (1. *горн.* тау токымнарын бораулап тишү приборы; 2. кәгазьгә, киноленталарга һ. б. тишекләр тишү приборы).

ПЕРФОРАЦИО'ННЫЙ *спец.* — перфорация...-ы, тишү...-ы, бораулау...-ы; *перфорационная машина* — перфорация машинасы, тишү (бораулау) машинасы.

ПЕРФОРА'ЦИЯ *ж. спец.* — 1. к. перфорировать; 2. *мед.* эренләп тишелү; *перфорация носовой перегородки* — борын пәрдәсенең эренләп тишелүе; 3. *кино, тех.* перфорация, кино лентасындагы тишекләр.

ПЕРФОРИ'РОВАТЬ *сов.* и *несов. спец. тех.* — бораулау, тишү (перфоратор белән бер-берсеннән билгеле бер ераклыкта торучы тишекләр ясау).

ПЕРФОРИ'РОВАТЬСЯ *несов. спец. страд.* — бораулану, тишелү (перфоратор белән).

ПЕРХА'ТЬ *несов. простореч.* — йөткерү, тамак кыру (тамак төбе кымырҗыганны бастыру өчен).

ПЕРХО'ТА *ж. мн.* нет, *простореч.* — тамак төбе кымырҗып тору.

ПЕ'РХОТЬ *ж. мн.* нет — кавык, кубык.

ПЕРХУ'Н *м.*, ПЕРХУ'НЬЯ *ж. просторе.* — еш йөткереп торучы, еш-еш тамак кыручы.

ПЕ'РЦЕВЫЙ — к. перцовый.

ПЕРЦЕПИ'РОВАТЬ *сов.* и *несов. филос.* — үзләштерү, төшенү, белеп алу, зиһенгә алу.

ПЕРЦЕПИ'РОВАТЬСЯ *несов. страд. филос.* — үзләштерелү, зиһенгә алыну.

ПЕРЦЕ'ПЦИЯ *ж. филос.* — зиһенгә алу, белеп алу, үзләштерү, сизү.

ПЕРЦО'ВКА *ж.* — 1. борычта төнәтелгән аракы; 2. әче гөмбәнең бер төре.

ПЕРЦО'ВОЧНЫЙ *разг.* — борычта төнәтелгән аракы...-ы; *перцовочный вкус* — борычта төнәтелгән аракы тәме.

ПЕРЦО'ВЫЙ — борычлы, борыч...-ы; *перцовая настойка* — борыч настойкасы.

ПЕРЧА'ТКА *ж.* — перчатка. ◇ **Бросить перчатку** — 1. *устар.* дуэльгә чакыру; 2. *перен.* көрәшкә чакыру, ярышка чакыру. **Поднять перчатку** — 1. *устар.* дуэльгә чакыруны кабул итү; 2. *перен.* көрәшкә (ярышка) чакыруны кабул итү.

ПЕРЧА'ТОЧНЫЙ — перчатка...-ы; перчатка бәйләү...-ы; *перчаточное производство* — перчатка производствосы; *перчаточный цех* — перчатка бәйләү цехы.

ПЕ'РЧЕНЫЙ *разг.* — борычлы, борыч салынган; *перченая капуста* — борычлы кәбестә.

ПЕ'РЧИК *м. разг. фам.* — борыч.

ПЕ'РЧИТЬ *несов. разг.* — борычлау, борыч сибү.

ПЕРШ *м. спец.* — перш (циркта акробатик хәрәкәтләр ясау мачтасы).

ПЕРШЕРО'Н *м.* — першерон (авыр йөк ташучы, үзенә бер төрле нәселле ат).

ПЕРШИ'ТЬ *несов. безл.* — тамак төбе кычыту, тамак төбе кымыржу, йөткерәсе килү, йөткерәсе килеп тору.

ПЁРЫШКО *ср. разг.* — 1. кечкенә генә каурый; 2. кечкенә каләм.

ПЁС *м.* — 1. эт; 2. ата эт; 3. *перен.* эт кеше (һәртөрле кабахәтлекләр эшләргә әзер торучы кеше). ◇ **Пёс его знает** *вульг.* — кем (эт) белсен аны.

ПЕ'СЕЛЬНИК *м. простореч. обл.* — к. песенник II в 1 знач.

ПЕ'СЕНКА *ж. разг.* — кечкенә генә җыр, матур җыр. ◇ **Песенка спета** — буласы булган инде; эше беткән инде; ашын ашаган, яшен яшәгән инде ул (карт кешегә карата).

ПЕ'СЕННИК I *м.* — җыр китабы, җырлар җыентыгы.

ПЕ'СЕННИК II *м.* ПЕ'СЕННИЦА *ж.* — 1. җырчы, хорда катнашучы; 2. җырлар авторы, җыр музыкасы композиторы.

ПЕ'СЕННЫЙ *муз. лит.* — җыр,..-ы; *песенный стиль* — җыр стиле.

ПЕСЕ'Ц *м.* — 1. ак төлке; 2. ак төлке мехы.

ПЁСИЙ *простореч.* — эт...-ы; *песья морда* — эт танавы.

ПЕСКА'РЬ *м.* — комкорсак, ташбаш (елгаларда яши торган вак балык).

ПЕСКИ' *только мн.* — ком чүле, ком даласы, комлык.

ПЕСКОРО'Й *м. зоол.* — комказыгыч (элпә канатлы бөҗәк).

ПЕСКОСТРУ'ЙНЫЙ *тех.* — ком ыргыткыч...; *пескоструйный аппарат* — ком ыргыткыч аппарат (таш стеналарны һәм металл конструкцияләрне чистарту һ. б. өчен кулланыла).

ПЕСНОПЕ'ВЕЦ *м. книж. ритор. устар* — 1. дини җырлар җырлаучы һәм чыгаручы; 2. *поэт.* шагыйрь.

ПЕСНОПЕ'НИЕ *ср. книж. устар.* — 1. *церк.* дини җыр, мөнаҗәт; 2. *поэт. ритор.* тантаналы җыр.

ПЕСНЬ *ж. книж.* — 1. *устар.* җыр; 2. *лит.* эпик поэманың аерым бүлеге. ◇ **Песнь песней** — җырлар җыры (зур иҗади әсәр турында).

ПЕ'СНЯ *ж.* — 1. җыр; 2. *перен. поэт.* лирик шигырь. ◇ **Старая песня** или **стара песня** *разг. неодобр.* — искергән җыр, искергән сүз, иске сүз, бер балык башы. **Тянуть** (или **петь**) **одну и ту же** (или **всё ту же**) **песню** *разг. фам.* — һаман бер нәрсәне туку, һаман бер балык башын чәйнәү. **Долгая песня** *перен.* — к. долгий. **Лебединая песня** — к. лебединый. **Песня спета** — к. песенка спета.

ПЕСО'К *м.* — 1. ком; 2. песок, шикәр комы; *сахарный песок* — шикәр комы.

◇ **Песок сыпется** *разг. шутл.* — комы коела (бик карт кеше турында). **Строить на песке** *книж. неодобр.* — төпсез, ышанычсыз дәлилләргә нигезләп кору.

**ПЕСО'ЧНИЦА** *ж.* — 1. *истор.* ком савыты (әүвәлдә киптергеч кәгазь барлыкка китерелгәнче язганны киптерү өчен кулланылган); 2. *ж.-д.* ком сиптергеч (моторлы вагонда, паровозда буксовать иттермәү өчен рельсларга автоматик рәвештә ком сиптерә торган резервуар).

**ПЕСО'ЧНЫЙ** — 1. ком...-ы; *песочные ванны* — ком ванналары; 2. *разг.* ком төсендәге; *песочное пальто* — ком төсендәге пальто; 3. *кулин.* таралып тора торган камырдан пешерелгән.

**ПЕССИМИ'ЗМ** *м. мн.* нет — 1. *филос.* пессимизм (дөньяда усаллык яхшылыктан күбрәк һәм дөнья тормышы ул—газап чигү генә дигән идеалистик караш); 2. өметсезлек, төшенкелек, дөньядан бизү.

**ПЕССИМИ'СТ** *м.*, **ПЕССИМИ'СТКА** *ж. книж.* — пессимист, пессимистка (1. *филос.* пессимизм карашын яклаучы; 2. өмете өзелгән кеше, төшенке күңелле кеше).

**ПЕССИМИСТИ'ЧЕСКИЙ** *книж.* — 1. төшенке, өмете өзелгән, күңелсез; *пессимистическое настроение* — төшенке күңел, төшенке настроение; 2. пессимизм...-ы; пессимистик; *пессимистическая философия* — пессимистик философия, пессимизм философиясе.

**ПЕССИМИСТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — төшенкелек, өметсезлек, рух төшенкелеге, пессимистлык.

**ПЕССИМИСТИ'ЧНЫЙ** *книж.* — к. пессимистический.

**ПЕСТ** *м.* — кисап, киле сабы, төйгеч. ◇ **Как пест в ложках** — кирәкле кишер яфрагы.

**ПЕ'СТАТЬ** *несов. простореч.* — к. пестовать.

**ПЕ'СТИК** I *м. бот.* — җимешлек (чәчәк аналыгы).

**ПЕ'СТИК** II *м.* — киле сабы.

**ПЕ'СТИКОВЫЙ** *бот.* — җимешлекле.

**ПЕ'СТОВАТЬ** *несов.* — 1. *устар.* карау, карап үстерү (баланы); 2. *перен.* тәрбияләп үстерү, кайгыртып үстерү.

**ПЕ'СТОВАТЬСЯ** *несов. обл.* — карау; *всю тёмну ноченьку пестовалась с больным ребёнком (Даль)* — караңгы төн буе авыру балаңы карап чыктым.

**ПЕСТРЕ'ТЬ** I *несов.* — 1. чуарланып тору, чуар булып күренү (чуар әйбер яки төрле төстәге әйберләр); 2. *(становиться пёстрым)* чуарлану, чуарлана бару.

**ПЕСТРЕ'ТЬ** II *несов.* — 1. күзгә күренеп тору, күзгә бәрелеп тору; *пестрят афиши на углах* — почмакларда афишалар күзгә бәрелеп тора; 2. *перен. разг.* еш кына очраштыргалау; еш очрау; *имя популярного писателя пестрит в газетах* — атаклы язучының исеме газеталарда еш очрый; *книга пестрит опечатками* — китапта хаталар еш кына очрый; 3. *разг.* артык чуарланып тору, чамадан тыш чуар булу; *обои пестрят, надо выбрать проще* — обойлар чамадан тыш чуар, гадирәкне сайларга кирәк.

**ПЕСТРЕ'ТЬСЯ** *несов. простореч.* — чуарланып тору, чуарланып күренү; *вдали пестреются цветы* — еракта чәчәкләр чуарланып күренеп торалар.

**ПЕСТРИ'НА** *ж. простореч.* — 1. *(пёстрая окраска)* чуарлык, чуар төс; 2. чуар тап, чуар бөрчек.

**ПЕСТРИ'ТЬ** *несов.* — 1. чуарлау; *пестрить ситец узорами* — ситсыны бизәкләр белән чуарлау; 2. *безл.* күз камашу; *в глазах пестрит от разноцветных флагов* — төрле төстәге флаглардан күз камаша.

**ПЕСТРОГЛА'ЗЫЙ** — чагыр күзле.

**ПЕСТРОПЛЕМЁННЫЙ** — күп милләтле, күп төрле милләтле, күп кабиләле, төрле милләт, төрле кабилә кешеләреннән торган.

**ПЕСТРОТА'** *ж. мн.* нет — чуарлык.

**ПЕСТРОТКА'ННЫЙ** *спец.* — чуар, төрле төстәге җепләрдән тукылган; *пестротканая ткань* — чуар тукыма.

**ПЕСТРУ'ШКА** *ж.* — 1. күтәмә, форель (балык); 2. төньяк йомраны.

**ПЁСТРЫЙ** — чуар; *пёстрая материя* — чуар материя; *пёстрый слог* — чуар стиль.

**ПЕСТРЯДЁВЫЙ** *спец.* — буй-буй чуар, алача...; *пестрядёвый сарафан* — алача сарафан (буй-буй чуар сарафан).

**ПЕСТРЯДИ'НА** *ж. мн.* нет, *спец. обл.* — к. пестрядь.

**ПЕСТРЯДИ'ННЫЙ** — алача...; *на нём пестрядинные, до клочьев истрёпанные портки и почти истлевшая рубашка* (Салтыков-Щедрин) — аның өстендә телгәләнеп беткән алача ыштан һәм бөтенләй диярлек череп беткән күлмәк.

**ПЕ'СТРЯДЬ** *ж. мн.* нет, *спец.* — алача, буй-буй чуар тукыма.

**ПЕ'СТУН** *м.*, **ПЕСТУ'НЬЯ** *ж.* — 1. *устар.* кайгыртучан тәрбияче, тәрбияләп үстерүче, карап үстерүче; 2. *обл.* (2—3 яшькә кадәр анасы янында яшәгән) аю баласы.

**ПЕСЦО'ВЫЙ** — 1. ак төлке...-ы; *песцовая шкура* — ак төлке тиресе; 2. ак төлке (мехыннан эшләнгән); *песцовый воротник* — ак төлке (мехыннан эшләнгән) яка.

**ПЕСЧА'НИК** *м. геол.* — комташ, комлы таш.

**ПЕСЧА'НИКОВЫЙ** *геол.* — ком ташлы; комлы таш...; *песчаниковая местность* — ком ташлы җир.

**ПЕСЧА'НКА** *ж. зоол.* — комлык тычканы.

**ПЕСЧА'НЫЙ** — комлы; *песчаный берег* — комлы яр.

**ПЕСЧИ'НКА** *ж.* — ком бөртеге; *песчинка в глаз попала* — күзгә ком бөртеге керде.

**ПЕТА'РДА** *ж. тех.* — петарда (1. *воен. истор.* берәр нәрсәне шартлату өчен эченә дары тутырылган металл савыт — снаряд; 2. *ж.-д.* тимер юл бозылып поезд йөреше өчен куркыныч туганда рельска салына һәм поезд басып үткәндә шартлап сигнал бирә торган кечкенә снаряд; 3. пиротехникада: эченә дары тутырылган кәгазь снаряд).

**ПЕТА'РДНЫЙ** *спец.* — петарда...-ы; *петардный шнур* — петарда шнуры.

**ПЕ'ТЕЛЬКА** *ж. разг.* — элмәк.

**ПЕ'ТЕЛЬНЫЙ** — элмәк...-ы; *петельный шов* — элмәк җөе.

**ПЕТИМЕ'ТР** *м. истор.* — петиметр (XVIII йөздә рус әдәбиятында купшы, җилкуар француз егетенең, шулай ук модада, кыланышта французларга сукырларча иярүче яшь рус дворянының сатирик образы).

**ПЕТИ'Т** *м. тип.* — петит (8 пункт зурлыгындагы вак шрифт).

**ПЕТИ'ТНЫЙ** *тип.* — петит...-ы, петиттан җыелган; *петитный набор* — петиттан җыелган набор.

**ПЕТИ'ЦИЯ** *ж. устар.* — петиция (күп кеше тарафыннан югары властька бирелә торган үтенеч язуы).

**ПЕТЛИ'ТЬ** *сов.* — үлем элмәге ясау (самолёт белән).

**ПЕТЛИ'ЦА** *ж.* — петлица (1. пиджакның, пальтоның кайтармасына беркетелгән элмәк; 2. форменный кием якасына төсле материядән тегеп куелган нашивка).

**ПЕ'ТЛЯ** и *обл.* **ПЕТЛЯ'** *ж.* — 1. элмәк; *обметать петли* — элмәкләрне юрмап чыгу; 2. тупса (ишек яки бераә капкач тупсасы); 3. кыл тозак; 4. *охот.* куян эзләре, җәнлек эзләре. ◇ **Завязать что-н. петлей** — берәр нәрсәне элмәкләп бәйләү. **Спустить петлю** — күзен җибәрү (шәл, оек кебекләрне бишинә белән бәйләгәндә). **Хоть в петлю лезь!** — кирәгем исә асылынып үл! (авыр хәлгә очраганда әйтелә). **Мёртвая петля** *ав.* — үлем элмәге. **Метать петли** *шутл. перен.* — 1. эзне яшерү; 2. эшне бутау.

**ПЕТЛЯ'ТЬ** *сов. простореч.* — адашып йөрү, әйләнеп йөрү (бер тирәдәрәк).

**ПЕТРИФИКА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *мин. геол.* — петрификация, ташка әверелү.

**ПЕТРО'В**: Петров день — Питрау (иске стиль буенча 29 ичы июнь).

**ПЕТРО'ГРАФ** *м. спец.* — петрограф (петрография белгече).

**ПЕТРОГРАФИ'ЧЕСКИЙ** *геол.* — петрографик; *петрографические исследования* — петрографик эзләнүләр (тикшеренүләр).

**ПЕТРОГРА'ФИЯ** *ж. мн.* нет, *геол.* — петрография (геологиянең тау токымнарының минераль составын, аларның урнашу шартларын һәм барлыкка килү тарихын өйрәнә торган бүлеге).

**ПЕТРОЛЕ'ЙНЫЙ** *науч.* — нефть...-ы; *петролейный эфир* — нефть эфиры.

**ПЕТРО'ЛЕУМ** *м. науч.* — нефть.

**ПЕТРОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет, *геол.* — к. петрография.

**ПЕТРУ'ШЕЧНИК** *м. театр.* — курчак кәмите күрсәтүче.

**ПЕТРУ'ШЕЧНЫЙ** *разг.* — петрушка...-ы; *петрушечные листья* — петрушка яфраклары.

**ПЕТРУ'ШКА I** *ж. мн.* нет — петрушка (яшькелт-сары чәчәкле яшелчә).

**ПЕТРУ'ШКА II** *м.* и *ж. мн.* нет, *театр* — 1. Петрушка (курчак театрында төп рольне башкаручы кәмит курчагы); 2. курчак театры; 3. *перен. простореч. фам.* ахмаклык, юләрлек; *вот какая петрушка получилась* — менә нинди ахмаклык килеп чыкты.

**ПЕТУ'Х** *м.* — 1. әтәч; 2. *перен. разг. неодобр.* әтәч, сугыш чукмары, бәйләнчек кеше. ◇ **До петухов (просидеть)** — таңга хәтле, әтәчләр кычкырганга чаклы (утыру). **С петухами (встать, подняться)** — таң тишегеннән тору. **Пустить красного петуха** — ут салу, ут төртү.

**ПЕТУ'ШИЙ** — әтәч...-ы; *петуший крик* — әтәч кычкыруы.

**ПЕТУШИ'НЫЙ** — к. петуший. ◇ **Петушиный голос** *перен.* — ачы тавыш, каты тавыш.

**ПЕТУШИ'ТЬСЯ** *несов. разг.* — әтәчләнү, кукраю; *ну и петушится!* — әтәчләнәме!

**ПЕТУШКО'М** *разг.* — ялагайланып кына артыннан яки яныннан (бару); *шёл петушком* — ялагайланып кына артыннан бара иде.

**ПЕТУШО'К** *м. разг.* — 1. әтәч, яшь әтәч; 2. уенчык әтәч.

**ПЕТЬ** *несов.* — 1. *(о человеке)* җырлау, көйләү; 2. *(о птицах)* сайрау; 3. *(о петухе)* кычкыру. ◇ **Ветер поёт** — җил улый. **Самовар поёт** — самовар шаулый (җырлый). **Что ты мне поёшь** *простореч. фам.* — нәрсә сөйлисең син миңа, нәрсә сайрыйсың син миңа. **Петь славу** — мактау, дан җырлау. **Лазаря петь** — сукрану.

**ПЕ'ТЬСЯ** *несов.* — җырлану, көйләнү.

**ПЕ'ТЯ** *м.* — әтәч (рус халык әкиятләрендә).

**ПЕХО'ТА** *ж. мн.* нет — пехота, җәяүле гаскәр.

**ПЕХОТИ'НЕЦ** *м.* — җәяүле гаскәри.

**ПЕХО'ТНЫЙ** — пехота...-ы, җәяүле гаскәр...-ы; *пехотный полк* — пехота полкы; *пехотный капитан* — пехота капитаны.

**ПЕ'ХТЕРЬ** *м. обл.* — 1. кәрзин; 2. *перен. простореч. пренебр.* килбәтсез, шыксыз кеше.

**ПЕХТУРА'** *ж. мн.* нет, *простореч. пренебр.* — җәяүлеләр.

**ПЕХТУРО'Й** *разг. фам. шутл.* — җәяү, җәяүләп; *ночью опоздал на трамвай, пришлось пехтурой идти* — төнлә трамвайга соңга калдым, җәяү барырга туры килде.

**ПЕЧА'ЛИТЬ** *несов.* — кайгыга салу, кайгыга төшерү, көенечкә салу, көендерү.

**ПЕЧА'ЛИТЬСЯ** *несов.* — кайгыга төшү, кайгыру, көенү, пошыну, сагышлану.

**ПЕЧА'ЛОВАТЬСЯ** *несов. устар.* — 1. к. печалиться; 2. кайгырту, яклау; *печаловаться о своих близких* — үз якыннарың турында кайгырту.

**ПЕЧА'ЛЬ** *ж.* — кайгы, хәсрәт, көенеч, эч пошу, сагыш.

**ПЕЧА'ЛЬНИК** *м.*, **ПЕЧАЛЬНИЦА** *ж. устар. теперь ирон.* — башкалар өчен көенүче, башкаларны кайгыртучы.

**ПЕЧА'ЛЬНЫЙ** — күңелсез, кайгылы, кызганыч, көенечле, үкенечле, аянычлы.

**ПЕЧА'ТАТЬ** *несов.* — 1. басу, бастыру (мәсәлән, китапны типографиядә, кулъязманы машинкада); 2. төшерү (негативтан кәгазьгә рәсем төшерү).

**ПЕЧА'ТАТЬСЯ** *несов.* — 1. *страд.* бастырылу, басылу; 2. үз әсәрләренне (китапларыны һ. б.) бастыру; *я в то время еще нигде не печатался* (М. Горький) — мин ул вакытта әле үз әсәрләремне беркайда да бастырмый идем.

**ПЕЧА'ТКА** *ж.* — 1. печать, кечкенә мөһер; 2. *спец.* (язулы яки бизәкле) бер кисәк; *печатка мыла* — бер кисәк сабын.

**ПЕЧА'ТНИК** *м. спец.* — печатник (полиграфия, китап басу производствосындагы специалист, эшче).

**ПЕЧА'ТНО** *нареч.* — матбугатта чыгып, матбугат аркылы; *печатно заявить о чём-н.* — матбугат аркылы берәр нәрсә турында белдерү.

**ПЕЧА'ТНЫЙ** — 1. китап басу...-ы, китап бастыру...-ы; *печатное дело* — китап басу эше; *печатный станок* — китап басу станогы; *печатный цех* — китап басу цехы; 2. басылган, бастырып чыгарылган; *печатная книга* — басылган китап; *печатная продукция* — бастырып чыгарылган продукция; 3. басма; *писать печатными буквами* — басма хәрефләр белән язу; 4. матбугатта чыккан, басылып чыккан; *печатные варианты стихотворения* — шигырьнең басылып чыккан вариантлары; 5. *нар.-поэт.* бизәлгән, печать басылган; *пряник печатный* — бизәлгән пряник.

**ПЕЧА'ТНЯ** *ж. устар.* — типография.

**ПЕЧА'ТОЧНИК** *м. спец.* — келәймәче.

**ПЕЧА'ТОЧНЫЙ** *спец.* — келәймәле, печатьле.

**ПЕЧА'ТЬ** *ж.* — 1. печать, мөһер; *печать учреждения* — учреждениенең печате (мөһере); 2. *перен. книж.* эз, билге; *печать времени* — заман эзе; *самодурства и лени печать* — ахмаклык һәм ялкаулык билгесе; *гениальное творчество Пушкина наложило свою печать на всю русскую поэзию* — Пушкинның гениаль иҗаты бөтен рус поэзиясенә үз иң эзен салды; 3. басу, басылу, бастыру, китап басу, басма; *книга всё ещё в печати* — китап һаман әле басылуда; *книга вышла из печати* — китап басылып чыкты; *книга готовится к печати* — китап басылуга хәзерләнә; 4. матбугат (басылган китаплар, газета-журналлар); *периодическая печать* — вакытлы матбугат; *работники печати* — матбугат работниклары; 5. басылу, басылган; *мелкая печать* — вак басылган; *чёткая печать* — ачык басылган.

**ПЕ'ЧЕВО** *ср. мн.* нет, *обл.* — күмәч, пешкән икмәк.

**ПЕЧЕНЕ'ГИ** *м. истор.* — печенеглар (IX—XI йөзләрдә Европаның көньяк-көнчыгышында күченеп йөргән һәм Киев Русена һөҗүмнәр ясап торган борынгы төрки халыкларның берсе).

**ПЕЧЕНЕ'ЖСКИЙ** *истор.* — печенеглар...-ы; *печенежские набеги* — печенеглар һөҗүме.

**ПЕЧЁНКА** *ж.* — 1. бавыр (суелган терлек бавыры); 2. *простореч. фам. шутл.* (печень) бавыр; *у меня печёнка болит* — бавырым авырта. ◇ **За печёнку берёт** — ачуны китерә, теңкәгә тия.

**ПЕЧЁНОЧНИК** *м. бот.* — бавырсыман мүк.

**ПЕЧЁНОЧНЫЙ** I *кулин.* — бавыр...-ы; *печёночный суп* — бавыр ашы; *печёночные артерии* — бавыр артерияләре. ◇ **Печёночный больной** — бавыры авырта торган авыру.

**ПЕЧЁНОЧНЫЙ** II *бот.* — бавырсыман; *печёночные мхи* — бавырсыман мүкләр.

**ПЕЧЁНЫЙ** — пешкән, пешерелгән (корылай, шулпасыз, сусыз); *печёный хлеб* — пешкән икмәк; *печёная картошка* — көлгә күмеп (мичкә тәгәрәтеп) пешерелгән бәрәңге.

**ПЕ'ЧЕНЬ** *ж. мн.* нет, *анат.* — бавыр.

**ПЕЧЕ'НЬЕ** *ср.* — 1. (корылай, сусыз пешерелгән) ашамлык; *в кладовой хранились разные соленья и печенья* — кладовойда төрле тозланган һәм пешерелгән ашамлыклар саклана иде; 2. печенье (төче камырдан хәзерләнгән ашамлык); *надо купить печенья к чаю* — чәйгә печенье сатып алырга кирәк.

**ПЕ'ЧИВО** — к. печево.

**ПЕЧИ'ЩЕ** *ср. спец.* — җимерек мич калдыклары.

**ПЕ'ЧКА** *ж. разг.* — мич. ◇ **Танцевать от печки** *разг. ирон.* — бер балык башын чәйнәү, шаблон буенча гына эшләү.

**ПЕЧНИ'К** *м.* — мич чыгаручы, мич салучы, мичче.

**ПЕЧНО'Й** — мич...-ы; *печная труба* — мич морҗасы.

**ПЕЧУ'РКА** *ж. разг.* — 1. тимер мич; 2. мич куышы.

**ПЕЧЬ** I *несов.* — 1. пешерү, салу (корылай, сусыз, шулпасыз, мәсәлән, икмәк, кабартма шикелле ашларны); *печь хлеб* — икмәк пешерү; 2. *разг.* кыздыру; *с утра нещадно пекло солнце (Шолохов)* — иртәдән кояш аяусыз кыздыра иде; *сегодня невыносимая жара, весь день печёт* — бүген түзә алмаслык эссе, көн буе кыздыра. ◇ **Как блины печь** *разг.* — бик тиз эшләү.

**ПЕЧЬ** II *ж.* — мич.

**ПЕ'ЧЬСЯ** I *несов. страд.* — пешерелү.

**ПЕ'ЧЬСЯ** II *несов. книж.* — кайгырту, яну, көю (берәр кеше турында).

**ПЕШЕДРА'ЛОМ** *разг. вульг.* — җәяү, җәяүләп.

**ПЕШЕХО'Д** *м.* — җәяүле, җәяү баручы.

**ПЕШЕХО'ДНЫЙ** — җәяү йөрү...-ы; җәяүлеләр...-ы; *пешеходное движение* — җәяүлеләр хәрәкәте; *пешеходный спорт* — җәяү йөрү спорты. ◇ **Пешеходная тропинка** — сукмак.

**ПЕШЕ'ЧКОМ** — к. пешочком.

**ПЕ'ШЕЧНЫЙ** *шахм.* — пешка...-ы; пешкалар...-ы; *пешечная атака* — пешкалар атакасы.

**ПЕ'ШИЙ** — 1. җәяүле; *пеший конному не товарищ* — җәяүле атлыга иш түгел; 2. *воен.* җәяүлеләр...-ы; *идти в пешем строю* — җәяүлеләр строенда бару; 3. *спец.* акрын йөгерүчән (эт турында); *эти собаки очень пеши* — бу этләр бик акрын йөгерүчән.

**ПЕ'ШКА** *ж.* — 1. пешка (шахматта иң

түбән бәяле шашка); 2. *перен. разг. фам.* әһәмиятсез кеше, вак кеше.

ПЕШКО'М *нареч.*— җәяү, җәяүләп; *идти пешком* — җәяү бару.

ПЕШНЯ' *ж.*— сөймән (боз ватуда кулланыла торган агач саплы авыр лом).

ПЕШО'ЧКОМ *разг. фам. шутл.*— җәяүләп, җәяү; *придётся вам пройтись пешочком* — сезгә җәяүләп барырга туры килер.

ПЕЩЕ'РА *ж.*— тау куышы, тау куышлыгы, тау тишеге, мәгарә.

ПЕЩЕ'РИСТЫЙ —1. тау тишекләре күп булган, мәгарәләргә бай; *пещеристый край* — мәгарәләргә бай край; 2. *анат.* болытсыман төзелешле; *пещеристые тела* — болытсыман төзелешле җисемнәр.

ПЕЩЕ'РНИК *м. устар.*— мәгарәдә (тау тишегендә) яшәүче.

ПЕЩЕ'РНЫЙ —1. тау тишеге...-ы; *пещерный ход* — тау тишеге юлы; 2. *палеон.* тау тишегендә яшәгән; *пещерный человек* — тау тишегендә яшәгән кеше, тау тишеге кешесе.

ПЕЩИ'СЬ *несов. старин.*— к. печься II; *о твоей судьбе сам буду я пещись* (*Пушкин*) — синең язмышың турында мин үзем кайгыртырмын.

ПЕ'ЩУР *м. обл.*— биштәр (аркага аса торган кабык савыт).

ПЕЩЬ *ж. книж. старин.*— мич; *пещь огненная* — утлы мич.

ПИ нескл. *ср. мат.*— пи (әйләнә озынлыгының диаметрга булган мөнәсәбәте).

ПИАЛА' *ж.*— касә.

ПИАНИ'ЗМ *м. мн.* нет, *муз.*— пианизм (фортепиано музыкасының аерым характерлы үзенчәлекләре, фортепианода уйнау сәнгате).

ПИАНИ'НО *ср.*— пианино (музыка коралы).

ПИАНИ'ССИМО *нареч. муз.* — пианиссимо, бик әкрен; *играть пианиссимо* — бик әкрен уйнау.

ПИАНИ'СТ *м.*— пианист (рояльдә уйнаучы, шул профессия белән шөгыльләнүче, рояльдә уйный белүче).

ПИАНИСТИ'ЧЕСКИЙ *муз.*— пианизм...-ы; пианистлык...-ы; *пианистическая культура* — пианизм культурасы; *пианистическая способность* — пианистлык сәләте.

ПИАНИ'СТКА *ж.*— пианистка (пианинода уйнаучы хатын-кыз).

ПИА'НО *нареч. муз.*— әкрен генә, йомшак кына (җырлау яки музыкаль инструментта уйнау турында).

ПИАНО'ЛА *ж. муз.*— пианола (фортепианода автоматик уйнау аппараты).

ПИА'СТР *м.*—1. горуш (Төркия, Мисыр, Сүрия, Ливан акчасы); 2. *истор.* пиастр (кайбер илләрдә акча берәмлеге).

ПИВА'ТЬ *несов.*— эчкәләү.

ПИВКО' *ср. мн.* нет, *простореч.*— сыра; *выпить бутылочку пивка* — бер шешә сыра эчү.

ПИВНА'Я — пивной, сыраханә.

ПИВНО'Й — сыра...-ы; *пивная пена* — сыра күбеге; *пивная бочка* — сыра мичкәсе.

ПИ'ВО *ср. мн.* нет — сыра. ◇ Пива не сваришь *с кем* — (аның белән) эшең пешмәс, борчагың пешмәс.

ПИВОВА'Р *м.*— сыра кайнатучы.

ПИВОВАРЕ'НИЕ *ср. мн.* нет — сыра кайнату.

ПИВОВА'РЕННЫЙ *м.*— сыра кайнату...-ы; *пивоваренный завод* — сыра кайнату заводы.

ПИВОВА'РНЯ *ж. устар.* и *обл.* — сыра кайнату заводы.

ПИВЦО' *ср. мн.* нет, *разг. фам.*— сыра.

ПИ'ГАЛИЦА *ж.* — 1. *зоол.* тәкәрлек (кош); 2. *разг.* (*о человеке*) арык, тәбәнәк, шыксыз кеше.

ПИГМЕ'Й *м.*—1. пигмей (бик тәбәнәк буйлы кеше); 2. *перен. презрит.* түбән кеше, адәм актыгы.

ПИГМЕ'НТ *м. физиол.*— пигмент (хайван яки үсемлек организмында тканьга төс кертә торган буяу матдәсе).

ПИГМЕНТА'ЦИЯ *ж. мн.* нет, *физиол.*— пигментация (хайван һәм үсемлек тканьнарында пигментның җыелуы).

ПИГМЕ'НТНЫЙ *тех.*— пигменттан хәзерләнгән; *пигментные красители* — пигменттан хәзерләнгән буяулар.

ПИ'ГОЛИЦА *ж.* к. пигалица.

ПИ'ГУС *м. обл.*— пигус (кыярлы әче шулпа).

ПИДЖА'К *м.*— пиджак.

ПИДЖА'ЧНИК *м. порт.*— пиджак тегүче.

ПИДЖА'ЧНЫЙ — пиджак...-ы; *пиджачная подкладка* — пиджак эчлеге.

ПИЕЛИ'Т *м. мн.* нет, *мед.*— пиелит (бөер лаканнарының ялкынсынуы).

ПИЕМИ'Я *ж. мн.* нет. *мед.*— пиемия (канда эрен барлыкка килү авыруы).

ПИЕ'СА — к. пьеса.

ПИЕТЕ'Т *м. мн.* нет, *книж.*— тирән хөрмәт, ихтирамлы мөнәсәбәт (берәр кешегә).

ПИЕТИ'ЗМ *м. мн.* нет — пиетизм (1. *религ. истор.* XVII йөзнең соңында протестантлар арасында килеп чыккан дини агым; 2. *книж.* мистик-дианәтчел тәкъвалык).

ПИЕТИ'СТ *м.*— пиетист (1. пиетизм тарафдары; 2. мистик күңелле кеше).

ПИЖА'МА *ж.*— пижама (өйдә кию өчен җиңел материядән тегелгән куртка һәм чалбар.)

ПИЖО'Н *м. разг. фам.*— пижон, кием калыбы (фырт егет).

ПИИ'Т и *старин.* ПИИ'ТА *м. книж. ритор. устар.*— шагыйрь.

ПИИ'ТИКА *ж. книж. ритор. устар.*— 1. поэтика; 2. поэзия сәнгате.

ПИИТИ'ЧЕСКИЙ *книж. ритор. устар. теперь только ирон.*— поэтик, шигъри.

ПИК I *м. геогр.*— очлы тау түбәсе, пик.

ПИК II *м. спец.*— пик (берәр эштә, берәр нәрсәнең агымында, берәр хәрәкәттә кыска вакытлы кискен күтәрелеш); *на улицах Москвы в часы пика можно наблюдать сплошные потоки автомобилей* — Москва урамнарында пик сәгатьләрендә

автомобильләрнең очсыз-кырыйсыз, тоташ агып торуын күзәтергә мөмкин.

**ПИ'КА** I *ж.*— сөңге.

**ПИ'КА** II *ж. простореч.*— пика (уен картасы, татарча карга дип тә йөртеләэ); *пойти пикой* — пика белән йөрү. ◇ **В пику (сделать, сказать)** *разг.*— үч итеп (эшләү, әйтү).

**ПИКАДО'Р** *м.*— пикадор (Испаниядә үгезләр сугышы вакытында үгезне сөңге белән котыртучы).

**ПИКА'НТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.*— 1. күнел ачучанлык; 2. кызыклылык; 3. ягымлылык, сөйкемлелек.

**ПИКА'НТНЫЙ** *разг.*— 1. әчкелтем тәмле; *пикантный соус* — әчкелтем тәмле соус; 2. *перен. фам.* кызыксыну тудыра торган, кызыксыну тудыручан, кызыклы; *пикантная новость* — кызыклы яңалык; 3. *фам.* үзенә җәлеп итә торган, дәрт уята торган.

**ПИКА'П** *м. спец.*— пикап (кечкенә генә йөк автомобиле).

**ПИ'КАТЬ** *несов. простореч.*— черелдәү (күбрәк кошлар турында).

**ПИКЕ'** I *ср.*— пике (1. киже-мамыктан эшләнгән тукыманың бер төре; 2. шундый тукымадан тегелгән әйбер; *рубашка-пике* — пике күлмәк).

**ПИКЕ'** II *ср. ав.*— пике (самолётның борыны белән аска таба очуы); *самолёт перешёл в пике* — самолёт пикегә күчте.

**ПИКЕ'ЙНЫЙ** — пике...; *пикейная рубашка* — пике күлмәк.

**ПИКЕ'Т** *м.*— пикет (1. *воен.* билгеле бер урындагы кечкенә сакчы отряд, хәрби дозор; 2. *полит.* капиталистик илләрдә: а. штрейкбрехерларны предприятиегә кертмәс өчен, предприятие капкасы янында тора торган эшчеләр группасы; б. демонстрацияләрне һөҗүм булу ихтималыннан саклап бара торган эшчеләр отряды; 3. *ж.-д.* тимер юлда юл үлчәү бервмлеге (километрның уннан бер өлеше); 4. *геодез.* геодезик съёмка вакытында берәр урынның югарылыгын билгеләү өчен алынган нокта; 5. *геодез.* җир үлчәве эшендә — җиргә кагып куела торган номерлы казык).

**ПИКЕТА'Ж** *м. мн.* нет, *геодез.*— пикетаж (нивелирлау алдыннан билгеле бер югарылыктагы ноктаЛарны рейка яки казыклар белән билгеләп чыгу).

**ПИКЕТАЖИ'СТ** *м. спец.*— пикетажист (пикетаж белгече).

**ПИКЕТА'ЖНЫЙ** *геодез.*— пикетаж...-ы; *пикетажные работы* — пикетаж эшләре.

**ПИКЕТИ'РОВАТЬ** *несов. полит.*— пикетлау, саклау; *пикетировать завод во время забастовки* — эш ташлау вакытында заводны пикетлау.

**ПИКЕТИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. полит.*— пикетлану, саклану.

**ПИКЕ'ТЧИК** *м. воен. устар.* и *полит.*— пикетчы (пикеттагы кеше, пикетта катнашучы).

**ПИ'КИ** *мн. простореч.*— к. пика II.

**ПИКИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— 1. *с.-х.* (казып алып) күчереп утырту (яшелчәне, яшь агачны сирәк итеп утырту); 2. пикировать итү (самолётның борыны белән 30°—70° почмак ясап түбәнгә таба очуы).

**ПИКИРОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* с.-х.— (казып алып) күчереп утыртылу.

**ПИКИ'РОВАТЬСЯ** *несов. разг.*— чәнечкеле сүзләр әйтешү, сүзгә килешү.

**ПИКИРО'ВЩИК** *м.*— пикировщик (пикировать итеп очар өчен җайлаштырылган самолёт).

**ПИ'ККОЛО** *ср. муз.*— пикколо (кайбер музыкаль инструментларның югары регистрлы бер төре).

**ПИ'КНИК** *м. науч.*— пикник (карсак гәүдәле, кыска муенлы, зур корсаклы симез кеше).

**ПИКНИ'К** *м.*— пикник, хозурга чыгу, сахрага чыгу, кырга чыгу (бер төркем иптәшләрнең кырга, урманга чыгып ачык һавада күңел ачулары).

**ПИКНО'МЕТР** *м. физ.*— пикнометр (каты һәм сыек җисемнәрнең тыгызлыгын үлчи торган прибор).

**ПИ'КНУТЬ** *сов. разг.*— 1. черелдәп кую; *птичка в клетке пикнула* — кошчык читлектә черелдәп куйды; 2. *перен. фам.* каршы әйтү, берәр сүз әйтү; *попробуй только пикнуть* — каршы әйтеп кенә кара, авызыңны ачып кына кара, тынынны чыгарып кына кара.

**ПИ'КОВЫЙ** — 1. пика...-ы; *пиковая масть* — пика масте (уен картасының); 2. *разг. шутл.* авыр, күңелсез; *пиковое положение* — авыр хәл. ◇ **Остаться при пиковом интересе** — коры калу, өмет бушка чыгу, уңышсызлыкка очрау.

**ПИКРИ'НОВЫЙ** *хим.*: **пикриновая кислота** — пикрин кислотасы (артиллериядә кулланыла торган шартлагыч, агулы кристаллик матдә).

**ПИКСАФО'Н** *м. мн.* нет, *апт.*— пиксафон (чәч юу өчен кулланыла торган дегетле сыек сабынның бер төре).

**ПИКТОГРАФИ'ЧЕСКИЙ** *этнол. филол.*— пиктография...-ы; пиктографик; *пиктографическое письмо* — пиктографик язу.

**ПИКТОГРА'ФИЯ** *ж. мн.* нет, *этнол. филол.*— пиктография (хәреф системасына хәтле булган, рәсемнәр ярдәмендә язылган иң борынгы язу системасы).

**ПИ'КУЛИ** *кулин.*— пикули (серкәгә салып маринадланган вак яшелчә).

**ПИЛА'** *ж.*—1. пычкы; *ручная пила* — кул пычкысы; 2. *перен. разг. неодобр.* мыгырдык кеше, йодәткеч кеше, бәйләнчек кеше.

**ПИЛА'В** *м. кулин.*— пылау.

**ПИЛА'-РЫ'БА** *ж. зоол.*— пычкы балык (акулага охшаган пычкысыман ерткыч балык).

**ПИЛЁНЫЙ** — кискән, киселгән, ярылган (пычкы белән); *пилёный лес* — (ярылган) такталар; *пилёная древесина* — киселгән агач. ◇ **Пилёный сахар** — шакмаклы шикәр.

**ПИЛИГРИ'М** *м.*, **ПИЛИГРИ'МКА** *ж. книж. истор.*—1. пилигрим (изге дип санала торган җирләргә гыйбадәт кылырга

баручы); 2. *перен.* юлаучы, узгынчы, дәрвиш.

**ПИЛИ'КАТЬ** *несов. разг. пренебр.*— чыелдату; *пиликать на скрипке* — скрипка чыелдату (уйный белми уйнап скрипкада начар тавышлар чыгару).

**ПИЛИ'ЛЬЩИК** *м.*—1. к. пильщик; 2. *зоол.* кискеч (элпә канатлы бөҗәк).

**ПИЛИ'ТЬ** *несов.*—1. (пычкы белән) кисү, яру; 2. *перен. разг. фам.* өзлексез тиргәп тору, мыгырдап йөдәтеп бетерү, тиргәп җәфалау, колак итен ашау.

**ПИЛИ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— (пычкы белән) киселү, ярылу; *твёрдое дерево пилится с трудом* — каты агач бик авырлык белән киселә.

**ПИ'ЛКА** *ж.*—1. (пычкы белән) кисү; *пилка дров* — утын кисү; 2. кечкенә пычкы.

**ПИ'ЛЛЕРС** *м. мор.*— пиллерс (судно палубасын астан тотып тору өчен куелган вертикаль борыс).

**ПИЛО'ВОЧНИК** *м. мн.* нет, *тех.*— такталык бүрәнә.

**ПИЛОМАТЕРИА'ЛЫ** *ед.* нет, *м. спец.*— агач материаллары (ярып-кисеп хәзерләнгән такталар, борыслар).

**ПИЛО'Н** *м. архит.*— пилон (1. капкала, күпер башында, зур бина ишеге алдында була торган, скульптур бизәкләр белән бизәкләнгән колонна, багана; 2. *истор.* борынгы Мисырда — кисек пирамида формасында ясалып, гыйбадәтханә каршына куелган манара).

**ПИЛООБРА'ЗНЫЙ** *спец.*— пычкысыман, тешле-тешле.

**ПИЛО'Т** *м. авиац.*— пилот (очу аппаратын, самолётны идарә итүче).

**ПИЛОТА'Ж** *м. мн.* нет, *ав.*— пилотаж (очу аппаратын идарә итә белү сәнгате).

**ПИЛОТИ'РОВАТЬ** *несов. ав.*— пилотировать итү, очу аппаратын идарә итү, самолётны (дирижабльне) йөртү.

**ПИЛОТИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. ав.*— идарә ителү, йөртелү (самолёт, дирижабль һ. б. очу аппаратлары).

**ПИЛО'ТКА** *ж.*— пилотка (хәрбиләрнең махсус формалы баш киеме, элек пилотларның баш киеме булган); *суконная пилотка* — сукно пилотка.

**ПИЛЬ** *междом. охот.*— кап! тот! элэктер! (эт өстерү сүзе).

**ПИ'ЛЬНЫЙ** *спец.*— пычкы белән кисү...-ы; такта яру...-ы; *пильные работы* — пычкы белән кисү эшләре.

**ПИ'ЛЬНЯ** *ж. спец.*— такта яру заводы.

**ПИ'ЛЬЧАТЫЙ** — пычкысыман кырыйлы; *пильчатые листья липы* — юкә агачының пычкысыман кырыйлы яфраклары.

**ПИ'ЛЬЩИК** I *м.*— (пычкы белән) такта яручы, утын кисүче.

**ПИ'ЛЬЩИК** II *м. зоол.*— кискеч (элпә канатлы бөҗәк).

**ПИЛЮ'ЛЬЩИК** *м. апт.*— пилюля ясаучы.

**ПИЛЮ'ЛЯ** *ж.* — пилюля (борчаксыман йомры дару). ◇ **Проглотить пилюлю** — үпкәләрлек сүзне дәшмичә тыңлау. **Отпустить пилюлю** — үпкәләрлек сүз әйтү, хәтер калдыру. **Позолотить пилюлю** — юмалау (берәр кешегә күңелсезлек эшләп, шул ук вакытта аны юмалау).

**ПИЛЯ'СТР** *м.*, **ПИЛЯ'СТРА** *ж. архит.*— пилястр (бер ягы белән стенага кереп торган дүрт кырлы колонна).

**ПИМОКА'Т** *м. обл.*— пима басучы, киез итек басучы.

**ПИМЫ'** *м.*— пима (1. *обл.* киез итек; 2. СССРдагы төньяк халыкларында булан тиресеннән тегелгән итек).

**ПИНАКОТЕ'КА** *ж. книж.*— картиналар җыелмасы, картиналар галереясы.

**ПИНА'ТЬ** *несов. простореч.*— тибү.

**ПИНА'ТЬСЯ** *несов. простореч.*— тибенү, тибешү.

**ПИНГВИ'Н** *м. зоол.*— пингвин (көньяк ярымшарда яши торган зур диңгез кошы).

**ПИНГ-ПО'НГ** *м. мн.* нет, *спорт.*— пингпонг (спорт уены, өстәл теннисы).

**ПИНО'К** *м. разг.*— каты итеп тибү, тибеп җибәрү.

**ПИ'НТА** *ж.*— пинта (Англиядә, Америкала сыек һәм бөртекле әйберләр үлчәү берәмлеге).

**ПИНЦЕ'Т** *м.*— пинцет, эскәк; *захватить занозу пинцетом* — тәнгә кергән шырпыны пинцет белән тартып алу.

**ПИ'НЧЕР** *м.*— пинчер (кыска йонлы, озын колаклы һәм озын койрыклы кечкенә эт).

**ПИО'Н** *м. бот.*— пион, чалма чәчәк.

**ПИОНЕ'Р** I *м.*— пионер (1 яңа, тикшерелмәгән җирләргә беренче буларак барып кергән кеше; 2. *перен.* фән, культура өлкәсендә берәр нәрсәне башлап ачкан, башлап җибәргән кеше).

**ПИОНЕ'Р** II *м.*, **ПИОНЕ'РКА** *ж.*— пионер, пионерка (10 яшьтән 15 яшькәчә булган балаларны эченә алган коммунистик оешма члены).

**ПИОНЕ'Р** III *м.*— пионер (кайбер илләрдә инженерлык гаскәрләре солдаты).

**ПИОНЕРВОЖА'ТЫЙ** *м.*, **ПИОНЕРВОЖА'ТАЯ** *ж.*— пионервожатый, пионерлар җитәкчесе (пионер отряды белән җитәкчелек итүче комсомолец).

**ПИОНЕ'РИЯ** *ж. мн.* нет — пионерлар.

**ПИОНЕ'РНЫЙ** *воен.* и *истор.*— инженерлык гаскәрләре солдаты...-ы; *пионерный заступ* — инженерлык гаскәрләре солдаты көрәге.

**ПИОНЕ'РСКИЙ** — пионерлар...-ы; пионер...-ы; *пионерский отряд* — пионерлар отряды; *пионерский значок* — пионер значогы.

**ПИОНЕ'РСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.*— пионерлык.

**ПИПЕ'ТКА** *ж. спец.*— тамызгыч, пипетка (тамчы тамызгыч); *пипетка глазных капель* — күзгә дару тамызгыч.

**ПИ'ПКА** *ж. старин.*— тәмәке трубкасы.

**ПИР** *м. устар.* *теперь ритор.*— 1. бик зур сый; мул сый, (күңел ачу, туй) мәҗлесе; 2. *перен.* гыйш-гишрәт, типтерү, котырыну. ◇ **В чужом пиру похмелье** — к. похмелье.

**ПИРАМИ'ДА** *ж.*— пирамида (1. *мат.* нигезе күппочмактан, яннары түбәләре бер булган өчпочмаклардан гыйбарәт җисем —

фигура; 2. *истор.* шуңа охшатып салынган дүрткырлы бик зур таш корылма, борынгы Мисырда фиргавеннәр каберлеге булып хезмәт иткән; 3. *перен.* кин нигезле һәм югарыга таба очлая барган әйберләр өеме; мәсәлән, икмәк магазины витринасында сохарилар пирамидасы; 4. *спорт.* бер-беренә баскан кешеләрдән ясалган пирамидасыман акробатик фигура; 5. *спорт.* уен башланыр алдыннан өчпочмак итеп тезелгән бильярд шарлары; 6. *анат.* чигә сөягенең бер өлеше).

**ПИРАМИДА'ЛЬНЫЙ** *книж.* — пирамидаль, пирамидага охшаган; *кучи песку пирамидальной формы* — пирамидага охшатып өелгән ком өемнәре.

**ПИРАМИДО'Н** *м. мн.* нет, *апт. мед.*— пирамидон (баш авыруыннан, невралгиядән һәм температураны төшерү өчен кулланыла торган дару).

**ПИРА'Т** *м.*— пират, диңгез юлбасары.

**ПИРА'ТСКИЙ** — 1. пиратлар...-ы; пират...-ы; *пиратское судно* — пиратлар судносы; 2. пиратларча...; *пиратские действия* — пиратларча эш итү.

**ПИРА'ТСТВО** *ср. мн.* нет — пиратлык, пиратлык итү, диңгездә талау.

**ПИРИ'Т** *м. мин.*— пирит (күкертле колчедан).

**ПИРОВА'ТЬ** *несов.*— сыйлану, туйда булу, мәҗлестә булу.

**ПИРО'Г** *м.*— 1. бәлеш, бөккән, пирог; 2. *разг.* торт; 3. *обл.* бодай икмәге, (кыл иләктән иләнгән оннан пешерелгән) икмәк. ◇ **Общественный или казённый пирог** *публиц. ирон.*— взятка алучылар, казна акчасын алучылар тарафыннан талана торган дәүләт яки җәмәгать милке. **Пирог с казённой начинкой** *публ. ирон. устар.*— к. общественный пирог. **Коксовый пирог** *тех.*— кокс пирогы (кокска әйләндерү өчен кыздырылган ташкүмер массасы).

**ПИРО'ГА** *ж.*— пирога (тар озын көймә, каранбларда һәм Океания халыкларында кулланыла).

**ПИРОГРАВЮ'РА** *ж. искус.* — пирогравюра (агачка яки күнгә яндырып төшерелгән рәсем).

**ПИРО'ЖНИК** *м.*— пирог сатучы, пирог салучы, пирог пешерүче.

**ПИРО'ЖНИЦА** *ж.*— 1. пирог сатучы, пирог салучы, пирог пешерүче (хатын-кыз); 2. *спец.* пирожный савыты (пирожный пешерү өчен форма).

**ПИРО'ЖНОЕ** *ср.*— пирожный (ашамлык).

**ПИРО'ЖНЫЙ** *спец.*— пирог...-ы; *пирожное тесто* — пирог камыры; *пирожная начинка* — пирог эче.

**ПИРОКСИЛИ'Н** *м. мн.* нет, *тех.*— пироксилин (шартлату эшләре башкару һәм төтенсез дары хәзерләү өчен кулланыла торган шартлагыч матдә).

**ПИРОКСИЛИ'НОВЫЙ** *тех.*— пироксилин (нан хәзерләнгән); *пироксилиновая шашка* — пироксилин(нан хәзерләнгән) шашка.

**ПИРО'МЕТР** *м. физ. тех.*— пирометр (бик югары температураны үлчәү приборы).

**ПИРОМЕ'ТРИЯ** *ж. мн.* нет, *физ.*— пирометрия (югары температураны үлчәү ысуллары турындагы тәгълимат).

**ПИРОСКА'Ф** *м. истор.*— пироскаф (пароходка беренче буларак бирелгән исем).

**ПИРОСКО'П** *м. физ. тех.* — пироскоп (югары температураларны якынча билгеләү өчен кулланыла торган җайланма).

**ПИРОТЕ'ХНИК** *м. спец.*— пиротехник (пиротехника белгече).

**ПИРОТЕ'ХНИКА** *ж. мн.* нет, *тех.*— пиротехника (фейерверклар, ракеталар, сигнал утлары һ. б. өчен тиз кабына һәм шартлый торган әйберләр хәзерләү сәнгате).

**ПИРОТЕХНИ'ЧЕСКИЙ** *тех.*— пиротехника...-ы; *пиротехническое искусство* — пиротехника сәнгате.

**ПИРУ'ШКА** *ж.* — кечкенә сый мәҗлесе.

**ПИРУЭ'Т** *м.*— пируэт (1. *театр.* танец вакытында бер аяк очына басып үз тирәндә бер кат әйләнү; сикергән вакытта һавада әйләнү; 2. *спец.* атның арткы аякларында әйләнүе; 3. *перен. шутл. ирон.* фикерләүдә, үз-үзеңне тотуда һ. б. кинәт борылыш, көтелмәгән сикереш).

**ПИ'РШЕСТВЕННЫЙ** *книж. ритор. устар.*— 1. мәҗлес...-ы; *пиршественный наряд* — мәҗлес киеме; 2. *перен.* тантаналы, бик зиннәтле.

**ПИ'РШЕСТВО** *ср. книж. ритор.*— мул сый мәҗлесе.

**ПИ'РШЕСТВОВАТЬ** *несов. книж. ритор. устар.*— к. пировать.

**ПИСА'КА** *м. разг. презрит.*— талантсыз язучы.

**ПИСА'НИЕ** *ср. книж.*— 1. (*действие*) язу; 2. (*то, что написано*) язылган әйбер. ◇ **Священное писание** *церк.*— изге китап (дини китаплар).

**ПИСАНИ'НА** *ж. мн.* нет, *разг. пренебр.*— язу, язылган әйбер; *бюрократическая писанина* — бюрократик язу; *маловразумительная писанина* — начар аңлаешлы язу.

**ПИ'САНЫЙ** — 1. язма..., язылма...; *писаный, а не печатный документ* — язма документ, басма документ түгел; 2. *устар.* и *обл.* бизәкле; *писаный пряник* — бизәкле прәнек. ◇ **Писаный красавец, писаная красавица** — бик чибәр кеше (ир кеше яки хатын-кыз). **(Говорить) как по писаному** *разг.*— бик шома (сөйләү).

**ПИ'САРСКИЙ** и **ПИСАРСКО'Й** — 1. писер...-ы, писерләр...-ы, писерлек...-ы: *писарская должность* — писерлек хезмәте; *писарский почерк* — писерләр почеркы; 2. писер язган; писер күчергән; *писарская копия* — писер күчергән копия.

**ПИ'САРЬ** *м.*— писер (1. *дорев.* отношениеләр язучы һәм язышулар алып баручы канцелярия хезмәткәре; 2. *истор.* күчереп язучы профессионал).

**ПИСА'ТЕЛЬ** *м.*, **ПИСА'ТЕЛЬНИЦА** *ж.*— язучы, әдип (әдәби әсәрләр авторы).

**ПИСА'ТЕЛЬСКИЙ** — язучы...-ы; язучылар...-ы; язучылык...-ы; әдиплек...-ы, *писательский труд* — язучылык хезмәте; *писательский талант* — язучылык таланты.

**ПИСА'ТЬ** *несов.*— 1. язу; 2. рәсем ясау.◇ **Пошла писать губерния** — к. губерния. **Писать вензеля** — к. вензель.

**ПИСА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. язылу; 2. *устар.* (*кем-чем*) булып саналу; *писаться торговцем* — сәүдәгәр булып саналу. ◇ **Нынче мне что-то не пишется** — бу арада мин ни өчендер яза алмыйм.

**ПИСЕ'Ц** *м.*— 1. *истор. лит.* күчереп язучы (борынгы Русьта); 2. *истор.* налог язучы (борынгы Русьта налог салырга мөмкин булган объектларны язып чыгучы); 3. писер.

**ПИ'СК** *м. мн.* нет — чыелдау тавышы.

**ПИСКА'РЬ** — к. пескарь.

**ПИСКЛЁНОК** *м. разг. фам. пренебр.*— чыелдык, елак (кечкенә балалар, чебиләр турында).

**ПИСКЛИ'ВЫЙ** — 1. чыелдык, чәрелдек, нәзек тавышлы; *писклывый голос* — чыелдык тавыш; 2. елак, бертуктаусыз елап торучы (бала турында); өзлексез чыелдап торучы (чебешләр турында); *пискливый ребёнок* — елак бала.

**ПИСКЛЯ'ВЫЙ** *просторечь.*— к. пискливый 1.

**ПИСКЛЯ'К** *м. просторечь. пренебр.*— чыелдык кеше.

**ПИ'СКНУТЬ** *сов. разг.*— 1. (*издать писк*) чыелдап кую; 2. *перен. просторечь.* к. пикнуть 2.

**ПИСКОТНЯ'** *ж. мн.* нет, *разг.*— чыелдашу, чыелдашып тору (мәсәлән, кошлар).

**ПИСКУ'Н** *м.*, **ПИСКУ'НЬЯ** *ж. разг. пренебр.* 1. (*тот, кто пищит*) чыелдык, чыелдаучы; 2. (*постоянно плачущий*) өзлексез елап торучы, елак; 3. (*о человеке с пискливым голосом*) чыелдык тавышлы кеше, чыелдык.

**ПИСНУ'ТЬ** *сов. просторечь. фам.*— язып ташлау (аз гына).

**ПИССУА'Р** *м.*— писсуар (бәдрәфтәге раковина).

**ПИСТОЛЕ'Т** *м.*— 1. пистолет (ату коралы); 2. *просторечь.* шаян малай, бик шук малай.

**ПИСТОЛЕ'ТНЫЙ** — пистолет...-ы; *пистолетный патрон* — пистолет патроны. ◇ **Пистолетный выстрел** — пистолеттан ату.

**ПИСТО'ЛЬ** I *м. истор.*— пистоль (роман илләрендә борынгы алтын акча).

**ПИСТО'ЛЬ** II *м.* и **ПИСТО'ЛЯ** *ж. устар.*— к. пистолет 1.

**ПИСТО'Н** *м.*— пистон (1. патронда, снарядта һ. б. эчено шартлаулы состав тотылган бакыр капсюль; 2. уенчык пистолетка куеп шартлату өчен, эченә аз гына дары салып ябыштырылган кәгазь кисәге; 3. *муз.* тынлы музыка коралының клапаны; 4. *спец.* катыргыдан, күннән ясалган әйберләрнең шнур кидертү өчен тишелгән тишекләренә ныгытылган металл кыса; 5. *ав.* самолёт төзү эшендә заклёпка урынына кулланыла торган махсус көпшә).

**ПИСТО'ННЫЙ** *спец.*—пистон...-ы, пистонлы; *пистонное ружьё* — пистонлы мылтык.

**ПИСУ'ЛЬКА** *ж. разг. шутл. фам.*— кечкенә генә хат, хат кисәге, записка, кош теледәй генә хат.

**ПИСУ'Н** *м. разг. презрит.*— начар язучы, талантсыз язучы.

**ПИСЧЕБУМА'ЖНЫЙ** — язу кәгазе...-ы; *писчебумажное производство* — язу кәгазе производствосы. ◇ **Писчебумажные принадлежности** — язу-сызу әсбаплары. **Писчебумажный магазин** — язу-сызу әсбаплары магазины.

**ПИ'СЧИЙ** — язу...-ы; *писчий материал* — язу материалы; *писчая бумага* — язу кәгазе; *писчие чернила* — язу карасы, кара.

**ПИ'СЫВАТЬ** *несов. разг.*—1. язгалау; 2. рәсем ясаштыргалау.

**ПИСЬМЕНА'** *устар. ед.* нет, *книж.*— язулар, язу билгеләре, хәрефләр; *египетские письмена* — Мисыр язулары.

**ПИ'СЬМЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет —1. (*графические знаки*) язу, әлифба; 2. язма хатирәләр, әдәби памятниклар; *древнерусская письменность* — борынгы рус язма әдәби памятниклары; 3. *устар.* (*грамотность*) грамоталылык, әдәби аң-белем; *процветание письменности* — әдәби аң-белемнең чәчәк атуы.

**ПИ'СЬМЕННЫЙ** — язу...-ы; язма...; язылган; *письменные знаки* — язу билгеләре; *письменная работа* — язма эш; *изложить своё мнение в письменном виде* — үз фикереңне язма рәвештә бирү.

**ПИСЬМЕЦО'** *ср. мн.* нет, *разг.*— хат кисәге, кечкенә хат, хат, кош теледәй генә хат.

**ПИСЬМО'** *ср.*—1. хат; *ценное письмо* — бәяле хат; 2. *истор.* кәгазь (официаль документ); *заёмное письмо* — заём кәгазе; *кредитное письмо* — кредит кәгазе; 3. язу, язу сәнгате; *искусство письма известно с очень древних времён* — язу сәнгате бик борынгы заманнардан бирле билгеле; *различные способы письма* — язуның төрле ысуллары; *история письма* — язу тарихы; *отношение письма к языку* — язуның телгә мөнәсәбәте; 4. язу, әлифба; *арабское письмо* — гарәп язуы (яки әлифбасы); *эволюция письма* — язу (әлифба) эволюциясе.

**ПИСЬМО'ВНИК** *м. истор.*—1. хат үрнәкләре җыентыгы; 2. тел һәм әдәбият буенча үзлегеңнән белем алу китабы.

**ПИСЬМОВОДИ'ТЕЛЬ** *м. спец. устар.*— канцеляриядә эш башкаручы, писер.

**ПИСЬМОВО'ДСТВО** *ср. мн.* нет, *спец.*— канцелярия эшләрен башкару, канцелярия эшләрен алып бару.

**ПИСЬМЕНО'СЕЦ** *м. офиц.*— хат ташучы, хатлар таратып йөрүче, почтальон.

**ПИТА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*—1. ашату; *искусственное питание больного* — авыруны ясалма рәвештә ашату; 2. тәэмин итеп тору, туендырып тору; *питание котла водой* — казанны су белән тәэмин итеп тору; 3. *физиол. мед.* ашау, азыкны үзләштерү; *у больного плохое питание* — авыру азыкны начар үзләштерә; 4. ашау, туену, азыклану, туклану; *усиленное питание* — яхшы ашау, гадәттәгедән ныграк ашау; *недостаточное питание* — җитәрлек булмаган туену (ашау); *общественное*

*питание* — җәмәгать тукландыну; 5. азык; *молочное питание* — сөт азыгы; *мясное питание* — ит азыгы.

**ПИТА'ТЕЛЬ** *м. тех.* — туендыргыч, туендыру клапаны (машиналарны су, ягулык белән туендыруны регулярлаштыра торган клапан).

**ПИТА'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — туклыклылык; *питательность пищи* — азыкның туклыклылыгы.

**ПИТА'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — 1 *науч.* туклыклы; *питательные вещества* — туклыклы матдәләр; *питательное блюдо* — туклыклы ашамлык; *питательный стол* — туклыклы азык (ашамлык); 2. туендыру...-ы; *питательный пункт* — туендыру пункты; 3. *спец.* (су, энергия кебекләр белән) тәэмин итү...-ы; *питательная станция* — (электр энергиясе һ. б. белән) тәэмин итү станциясе. ◇ **Питательная среда** *книж.* — 1. *биол.* берәр организмның яки үсемлекнең үсүенә мөмкинлек бирә торган тирәлек; 2. *перен.* берәр иҗтимагый күренешнең ныгуына, үсүенә азык бирә торган (мөмкинлек бирә торган) среда; *мелкое крестьянское хозяйство — питательная среда для возникновения и роста капиталистических элементов* — вак крестьян хуҗалыгы — капиталистик элементларның барлыкка килүенә һәм үсүенә азык бирә торган среда.

**ПИТА'ТЬ** *несов. книж.* — 1. ашату, туендыру, азыкландыру, азык бирү; *питать больного четыре раза в день* — авыруны көнгә дүрт мәртәбә ашату; 2. туендыру, азык бирү, тәэмин итеп тору; *каменный уголь питает промышленность* — промышленностьны ташкүмер туендыра; *питать котлы водой* — казаннарны су белән тәэмин итеп тору; 3. *перен.* тудыру, үстерү, арттыру, ныгыту; *дружба питает взаимное доверие* — дуслык бер-береңә ышанычны ныгыта. ◇ **Питать надежду** — өмет итү. **Питать ненависть** — күрә алмау, нәфрәт саклау. **Питать уверенность** — ышаныч тоту, ышанып тору.

**ПИТА'ТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. ашау, туклану, азыклану, туену, ризыклану; *питаться мясом и рыбой* — ит һәм балык белән туклану; 2. файдалану, туену; *Магнитогорск питается местным углем* — Магнитогорск җирле күмердән файдалана; 3. *страд.* туендырылу, ашатылу, тукландырылу.

**ПИТЕ'ЙНЫЙ** *устар.* — (исерткеч) эчү...-ы; *питейный дом* — эчү йорты.

**ПИТЕКА'НТРОП** *м. палеон.* — питекантроп (кешегә охшаган казылма зат).

**ПИ'ТЕРСКИЙ** *разг. дореvол.* — Питер...; *Питерские рабочие — передовики русского пролетариата* — Питер (Петербург) эшчеләре — рус пролетариатының алдынгылары.

**ПИ'ТЕРЩИК** *м. разг. устар.* — Питерчы (Питерда, ягъни Петербургта булган, күпне күргән кеше); *Филипп Корчагин питерщик, по мастерству печник (Некрасов)* — Филипп Корчагин Питерчы, һөнәре белән мичче.

**ПИТИЕ'** *ср. церк. книж. устар. теперь шутл.* — эчү (күбесенчә исерткеч эчемлекләр эчү турында).

**ПИТО'МЕЦ** *м.*, **ПИТО'МИЦА** *ж. книж. поэт.* — (берәүнең) тәрбияләгән кешесе, тәрбияләгән шәкерте, асрап үстергән баласы; *Пушкин — питомец царскосельского лицея* — Пушкин Царское Село лицеенда тәрбияләнгән кеше.

**ПИТО'МНИК** *м.* — питомник, үрчеткеч урын (1. *спец.* үсемлек яки хайваннарны үстерү, үрчетү урыны; 2. *перен. книж.* берәр өлкәдә эшләргә әзерләнә торган эшлекелләрне җитештерү, тәрбияләү урыны).

**ПИТО'МНИЧЕСКИЙ** *спец.* — питомник...-ы; *питомническое хозяйство* — питомник хуҗалыгы.

**ПИТО'Н** *м. зоол.* — питон (эре тропик елан).

**ПИТУ'Х** *м. простореч. фам.* — эчкече, бик күп эчүче, исерек баш.

**ПИТЬ** *несов.* — эчү; *пить чай* — чәй эчү. ◇ **Вашими бы устами да мёд пить** — авызыңа бал да май. **Не пито не едено** *простореч.* — чамадан тыш күп акча туздыру. **Как пить дать** *разг.* — һичшиксез, шөбһәсез.

**ПИТЬЁ** *ср.* — 1. (*действие*) эчү; 2. (*то, что пьётся*) эчемлек.

**ПИТЬЕВО'Й** — эчә торган, эчәргә яраклы; *питьевая вода* — эчәргә яраклы су.

**ПИ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — эчелү (су, эчемлек һ. б.).

**ПИФАГОРЕИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *истор. филос.* — пифагореизм (борынгы грек философы Пифагор өйрәтмәсе; бу өйрәтмә үлемсезлекне, җанның теге дөньяга күчүен яклый, галәмне гармониягә һәм санга буйсынган төзек бер бөтен итеп карый).

**ПИФАГОРЕ'ЙСТВО** *ср. мн.* нет, *истор. филос.* — к. пифагореизм.

**ПИФАГОРЕ'ЙЦЫ** *м. истор. филос.* — пифагорчылар (Пифагор шәкертләре, пифагореизм тарафдарлары).

**ПИФАГО'РОВ:** **пифагорова теорема** *мат.* — Пифагор теоремасы (бу теорема буенча гипотенуза өстенә корылган квадратлар катетлар өстенә корылган квадратлар суммасына тигез); **пифагоровы штаны** *школьн. фам.* — пифагор штаны (шушы ук теореманың шаяртып әйтелә торган исеме).

**ПИ'ФИЯ** *ж.* — Пифия (борынгы грек мифологиясе буенча Аполлон храмында теленә ни килсә шуны сөйләп пәйгамбәрлек иткән хатын. Бу сүз күчермә мәгънәдә күп кулланыла).

**ПИХА'ТЬ** *несов. разг.* — 1. (көчле итеп) төртү, этеп җибәрү, (тупас итеп) төртү; *пихать кого-н. локтями* — кемне булса да терсәк белән төртү; 2. төртеп (этәреп) илтү; *пихать тачку* — тачканы төртеп илтү; 3. тыгу; *пихать ногу в сапог* — аякны итеккә тыгу; *пихать вещи в чемодан* — әйберләрне чемоданга тыгу.

**ПИХА'ТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. этенү, төртенү; *чего ты пихаешься?* — нәрсә син төртенәсең? 2. төртешү; *мальчики пихаются — кто кого свалит* — малайлар кем

кемне егар икән дип төртешәләр; 3. тыгылу, тутырылу; *второпях вещи пихались в чемодан как попало* — ашыгыч булганлыктан, әйберләр чемоданга ничек житте алай тутырылдылар.

**ПИХНУ'ТЬ** *сов. разг.* — төртеп жибәрү, тыгып кую.

**ПИ'ХТА** *ж.* — ак чыршы.

**ПИ'ХТОВЫЙ** — ак чыршы...-ы; *пихтовый лес* — ак чыршы урманы.

**ПИ'ЧКАТЬ** *несов. разг.* — 1. (көчләп) күп ашату, (көчләп) күп эчертү, тыгындыру; 2. *перен.* (*заполнять чем-н. сверх меры*) юк-бар нәрсә белән башын катыру.

**ПИ'ЧКАТЬСЯ** *несов. разг. страд.* — көчләп күп ашатылу, көчләп күп эчертелү, тыгындырылу.

**ПИЧУ'ГА** и чаще **ПИЧУ'ЖКА** *ж. разг.* — кошчык.

**ПИ'ШУЩИЙ** — 1. язучы; *пишущий эти строки* (*книж.*) — өшбуны язучы; 2. язу...-ы; *пишущая машинка* — язу машинкасы. ◇ **Пишущая братия** *фам.* — язучылар, әдипләр.

**ПИ'ЩА** *ж. мн.* нет — 1. ашамлык, жим, азык, аш, ризык; аш-су; 2. *перен.* азык (акыл өчен, фикер өчен); *в этой книге мало пищи для ума* — бу китапта акыл өчен азык аз. ◇ **Давать пищу** (*чему*) *книж.* — сылтау тудыру, (берәр нәрсәнең) таралуына ярдәм итү; *давать пищу сплетням* — гайбәт таратуга сылтау тудыру. **На пище святого Антония** *книж. шутл.* — ачлы-туклы.

**ПИЩА'ЛКА** *ж. простореч. обл.* — сыбызгы.

**ПИЩА'ЛЬ** *ж.* — пищаль (1. *устар.* курайсыман тынлы музыкаль инструмент; 2. *истор.* элекtә Россиядә — пушка, соңрак озын авыр мылтык).

**ПИЩА'ТЬ** *несов.* — 1. чыелдау, чикылдау; 2. чыелдап сөйләү; 3. *простореч. перен.* (*плаксиво жаловаться*) елап-елап зарлану.

**ПИЩЕВАРЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *физиол. мед.* — аш сеңү, аш кайнау, аш кайнату (ашказанында).

**ПИЩЕВАРИ'ТЕЛЬНЫЙ** *анат. физиол. мед.* — аш кайнату...-ы, аш сеңү...-ы; азык үзләштерү...-ы, *пищеварительные процессы* — аш кайнату процесслары.

**ПИЩЕВИ'К** *м.* — азык-төлек промышленносте эшчесе; *союз пищевиков* — азык-төлек промышленносте эшчеләре союзы.

**ПИЩЕВКУСОВО'Й** *спец.* — азык-төлек...-ы; *пищевкусовая промышленность* — азык-төлек промышленносте.

**ПИЩЕВО'Д** *м. анат.* — үңәч (азык юлы).

**ПИЩЕВО'Й** — азык...-ы, азык-төлек...-ы; *пищевые продукты* — азык продуктлары; *пищевые вещества* — азык матдәләре; *пищевая промышленность* — азык-төлек промышленносте.

**ПИ'ЩИК** *м.* — сыбызгы (1. *охот.* кош аучылары сыбызгысы; 2. тынлы музыкаль инструментларда тавыш чыгара торган пластинка).

**ПИЭТЕ'Т, ПИЭТИ'ЗМ, ПИЭТИ'СТ** — к. пиетет, пиетизм, пиетист.

**ПИЯ'ВКА** *ж. мед.* — 1. сөлек; *ставить пиявки* — сөлек салу; 2. *перен. разг.* (*о человеке*) канэчкеч.

**ПЛАВ** *м. мн.* нет, *спец.*: **корабль на плаву** — корабль су өстендә, корабль суда (дингездә) чакта.

**ПЛА'ВАНИЕ** *ср.* — 1. *только ед.* йөзү, йөзеп йөрү; *плавание в море* — диңгездә йөзү; 2. (суднода) сәяхәт итү; *дальнее плавание* — (суднода) ерак сәяхәт, ерак сәфәр; *отправиться в плавание* — ерак сәфәргә чыгу (суднода). ◇ **Школа плавания** — йөзәргә өйрәтү мәктәбе.

**ПЛА'ВАТЕЛЬНЫЙ** *спец.* — йөзү...-ы; *плавательная перепонка у птиц* — кошларның йөзү ярысы; *плавательные пузыри* — йөзү куыклары (балыкта).

**ПЛА'ВАТЬ** *несов.* — 1. йөзү, йөзеп йөрү; *мальчики плавают в речке* — малайлар елгада йөзәләр; 2. *перен. ирон. и школьн. арго* йөзү, сай йөзү; *он плавает на экзамене* — ул экзаменда сай йөзә. ◇ **Плавать в крови** *книж. ритор.* — кан эчендә яту. **Мелко плавать** *разг. пренебр.* — сай йөзү (әһәмиятсез, сәләтсез кеше турында әйтелә). **Дерево плавает в воде** — агач суда батмый.

**ПЛА'ВЕНЬ** *м.* — 1. беркеткеч, ныгыткыч (а. силикат производствосында яндырыла торган балчыкка аның аерым состав кисәкләрен яхшырак беркетү өчен кушыла торган матдә, мәсәлән, акбур, кыр шпаты; б. ялтыравык — глазурь — йөгертелгән чүлмәкнең буявын ныгыту өчен кулланыла торган катнашма); 2. эреткеч (металлургиядә руданы эреткән вакытта андагы матдәләрнең эрүен көчәйтү өчен салына торган матдә).

**ПЛАВИ'К** *м. мн.* нет, *мин.* — плавик (төрле төстәге кристаллар формасындагы ялтыравыклы минерал).

**ПЛАВИКО'ВЫЙ**: **плавиковый шпат** *мин.* — к. плавик; **плавиковая кислота** *хим.* — плавик кислотасы (фторлы водородның суда эремәсе, пыяланы ашый торган агулы кислота).

**ПЛАВИ'ЛЬНИК** *м. тех.* — металл эреткеч (прибор).

**ПЛАВИ'ЛЬНЫЙ** *тех.* — металл эретү...-ы; *плавильный завод* — металл эретү заводы; *плавильная печь* — металл эретү миче.

**ПЛАВИ'ЛЬНЯ** *ж. тех.* — металл эретү урыны, металл эретү бинасы.

**ПЛАВИ'ЛЬЩИК** *м. спец.* — металл эретүче (эшче, белгеч).

**ПЛА'ВИТЬ** *несов.* — 1. *тех.* эретү (каты матдәләрне, күбесенчә металлны); *плавить металл* — металл эретү; *плавить стекло* — пыяла эретү; 2. *обл. спец.* агызу; *плавить плоты* — сал агызу.

**ПЛА'ВИТЬСЯ** *несов.* — 1. *тех.* эрү (металл турында); 2. *страд.* эретелү.

**ПЛА'ВКА** *ж. спец.* — 1. эретү; *плавка металлов* — металларны эретү; 2. (сал) агызу; *плавка плотов* — сал агызу; 3. эретем; *первые две плавки дали 250 тонн чугу-*

***на*** — беренче ике эретем 250 тонна чуен бирде; ***получены первые плавки чугуна*** — чуенның беренче эретемнәре алынды.

**ПЛА'ВКИ** *ед.* нет, *спорт.*— плавки (коенганда киелә торган махсус трусиклар).

**ПЛА'ВКИЙ** —эри торган, эрүчән (мәсәлән, металл).

**ПЛА'ВКОСТЬ** *ж. мн.* нет, *спец.*— эрүчәнлек; *плавкость металла* — металлның эрүчәнлеге.

**ПЛАВЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *спец.*— эрү (металл һ. б. каты матдәләр); *точка плавления* — эрү ноктасы (матдәне эретә алырлык температура).

**ПЛА'ВЛЕНЫЙ** *спец.*: **плавленый сыр** — йомшак сыр; **плавленый мел** — бик вак итеп төелгән акбур (резина производствосында кулланыла).

**ПЛА'ВНЕВЫЙ** *спец.*— камыш һәм әрәмә үскән тугайлар...-ы; *плавневые почвы* — камыш һәм әрәмә үскән тугайлар туфрагы.

**ПЛА'ВНИ** *мн.*— камыш үскән тугайлар, су баса торган тәбәнәк яр буйлары һәм утраулар (Днепр, Днестр, Дунай, Кубань елгалары буйларында).

**ПЛАВНИ'К** *м. зоол.*— йөзгеч, балык канаты; *парные плавники* — парлы йөзгечләр (корсак һәм күкрәктәгеләр); *непарные плавники* — сыңар йөзгечләр (балыкның сыртында һәм койрыгында).

**ПЛАВНО'Й** *спец.*— 1. *(пригнанный водой)* агызып китерелгән (мәсәлән, сал); 2. *(пловучий)* йөзмә, йөзеп йөрмәле (балык тоту ятьмәсе турында әйтелә); *плавная сеть* — йөзмә ятьмә (беркетеп куелган түгел).

**ПЛА'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— тигезлек, шомалык, салмаклык; *плавность походки* — йөрешнең салмаклыгы; *плавность стихов* — шигырьнең салмаклыгы; *плавность речи* — сөйләмнең шомалыгы.

**ПЛА'ВНЫЙ** — салмак; *плавная походка* — салмак йөреш; *плавная мелодия* — салмак көй; ◇ **Плавные согласные** *лингв.*— йөзмә тартыклар (мәсәлән, „р", „л").

**ПЛАВУ'Н** *м. спец.*— к. плывун.

**ПЛАВУНЕ'Ц** *м. зоол.*— йөзгәләк (су коңгызы).

**ПЛАВУ'ЧЕСТЬ** *ж. мн.* нет, *спец.*— йөзү сәләте, йөзә алучанлык; *плавучесть судна* — судноның йөзү сәләте.

**ПЛАВУ'ЧИЙ** — 1. йөзмә, йөзеп йөри торган; *плавучие льдины* — йөзеп йөри торган бозлар; *плавучий мост* — йөзмә күпер; 2. суда батмый торган; *плавучий материал* — суда батмый торган материал.

**ПЛА'ВЩИК** *м. спец.*—1. к. плавильщик; 2. *обл.* сал агызучы.

**ПЛАВЬ** *ж. мн.* нет, *спец.*— эретелгән чуен.

**ПЛАГИА'Т** *м. книж., право* — плагиат, әдәби караклык (чит кешенең әсәрен, хезмәтен яки чит кеше әсәренең кайбер өлешләрен урлап, үзенеке иттереп бастырып чыгару).

**ПЛАГИА'ТОР** *м. книж. право* — плагиатор, әдәбият карагы, плагиат белән шөгыльләнүче.

**ПЛАГИА'ТОРСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.*— плагиаторлык, әдәби караклык.

**ПЛАГИИ'РОВАТЬ** *несов. книж. редко* — плагиаторлык итү, урлау (чит кеше фикерен, чит кеше хезмәтен); *плагиировать чужую идею* — чит кеше идеясен урлау.

**ПЛАГИИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. книж. редко* — урлану (чит кеше фикере, чит кеше әсәре, хезмәте).

**ПЛА'ЗМА** *ж.*— плазма (органик тканьнарның — канның һәм лимфаның сыек өлеше).

**ПЛАЗМАТИ'ЧЕСКИЙ** *биол.*— плазматик (плазмадан торган); *плазматическая клетка* — плазматик күзәнәк.

**ПЛАЗМО'ДИЙ** *м. биол.*— плазмодий (1. үсемлекләрнең черек калдыкларында, агач төпләрендә, коелган яфракларда була торган лайласыман гөмбәләр массасы; 2. саз бизгәге паразиты — паразитик рәвештә канда яши торган лайлалы төерсыман гади организм).

**ПЛА'КАЛЬЩИК** *м.*, **ПЛА'КАЛЬЩИЦА** *ж.*— 1. *устар.* елланып елаучы (әүвәлге вакытта — үлекне озатканда яки искә төшергәндә); 2. *разг. пренебр.* елак, (бертуктаусыз үз тормышыннан) зарланучы.

**ПЛАКА'Т** *м.*— плакат (1. яхшы күренерлек җиргә элеп куела торган зур рәсемле игълан; 2. көчле тәэсир бирә торган лозунглы агитацион рәсем; 3. *истор. офиц.* имана түләүче сословие вәкилләренә бирелә торган паспорт).

**ПЛАКАТИ'СТ** *м. спец.*— плакатист, плакатчы художник.

**ПЛАКА'ТНЫЙ** — плакат...-ы; *плакатная мастерская* — плакат мастерское. ◇ **Плакатный паспорт** *дореВол. офиц.*— к. плакат 3.

**ПЛАКА'ТЧИК** *м.*— плакатчы (плакат хәзерләүче художник яки эшче).

**ПЛА'КАТЬ** *несов.*— 1. елау; балавыз сыгу; 2. *перен. разг. обл.* тирләү; *окна плачут* — тәрәзәләр тирләгән. ◇ **Плакали денежки** *разг. фам.*— акчабыз әрәмгә китте.

**ПЛА'КАТЬСЯ** *несов.*— 1. *разг.* зарлану; сукрану; *плакаться отцу* — әтигә зарлану; 2. *безл.* елыйсы килү, еларга хәзерләнеп тору.

**ПЛАКЕ'** *спец. торг.*— плаке (өстенә алтын яки көмеш йөгертеп ясалган әйбер).

**ПЛАКИРОВА'ЛЬНЯ** *ж. спец.*— плакирлау мастерское.

**ПЛАКИРОВА'ЛЬЩИК** *м.*— к. плакировщик.

**ПЛАКИРОВА'ТЬ** *сов* и *несов. спец.*— плакирлау (1. җиз һәм бакырдан ясалган әйбер өстенә алтын яки көмеш кебек тутыкмый торган металл йөгертү; 2. гади агачтан ясалган әйбер өстенә кыйммәтле агачтан юка катлау ябыштыру; 3. юылудан яки шуышудан саклау өчен туфрак өемнәре кырыйларына кәс җәю).

**ПЛАКИРОВА'ТЬСЯ** *несов. спец. страд.*— плакирлану.

**ПЛАКИРО'ВОЧНЫЙ** *спец.*—плакирлау...-ы

*плакировочная мастерская*—плакирлау мастерское.

**ПЛАКИРО'ВЩИК** *м. спец.*— плакирлаучы.

**ПЛА'КСА** *м.* и *ж. разг. пренебр.*— елак (күбесенчә бала турында).

**ПЛАКСИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — елаклык.

**ПЛАКСИ'ВЫЙ** *разг. неодобр.*— 1. елак, чытык, һаман еларга торучы; *плаксивый ребёнок* — елак бала; 2. *перен.* елак, кайгылы, күңелсез, моңсу, кызганыч; *плаксивый голос* — елак тавыш.

**ПЛАКУ'Н** I *м.* и **ПЛАКУ'Н-ТРАВА'** *ж. обл.*— дару үләне (кырлыган һ. б.).

**ПЛАКУ'Н** II *м. зоол.*— диңгез моллюскы.

**ПЛАКУ'ЧИЙ** *обл.*— елак, һаман елап торучы. ◇ **Плакучая ива** *бот.*— бөдрә тал.

**ПЛАКУ'ША** *ж. обл.*— к. плакальщица.

**ПЛАМЕНЕ'ТЬ** *несов. книж. поэт. устар.*— 1. ялкынланып яну; 2. *перен.* ... утында яну; *пламенеть любовью* — гыйшык утында яну.

**ПЛАМЕНИ'СТЫЙ** — ялкынлы, ялкынланып яна торган.

**ПЛА'МЕННИК** *м.*— 1. *книж. поэт. устар.* факел; 2. *бот.* ут үләне.

**ПЛА'МЕННО** *нареч.*— ялкынланып, кызып-кызып; *пламенно спорить* — кызыпкызып бәхәсләшү.

**ПЛА'МЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— ялкынлылык; *пламенность воображения* — хыялның ялкынлылыгы.

**ПЛА'МЕННЫЙ** *книж. поэт.*— 1. ялкынлы, кызу, дәртле; *пламенный привет* — ялкынлы сәлам; 2. алсу; *пламенные зори* — алсу таңнар.

**ПЛА'МЕНЬ** *м. мн.* нет, *книж. поэт. устар.*— к. пламя.

**ПЛАМЕОБРА'ЗНЫЙ** *спец. книж.*— ялкынсымак, ялкынсыман; *пламеобразное излучение* — ялкынсыман балку.

**ПЛА'МЯ** *ср. книж.*— 1. ялкын; *пламя от костра* — костёр ялкыны; 2. *перен. поэт. устар.* ялкын, дәрт, дулкынлану, дәртләнү; *любовное пламя* — мәхәббәт ялкыны.

**ПЛАН** *м.*— план (1. берәр әйберне, урынны яки корылышны туры горизонталь проекция методы белән күрсәткән сызым; *план здания* — бина планы; 2. алдан уйланып куелган эш тәртибе, проект, бирем, задание; *разработать план чего-н.* — берәр эшнең планын төзү; *план осуществления чего-н.*— берәр эшне башкарып чыгу планы; *строго обдуманный план научного сочинения* — фәнни хезмәтнең җентекләп уйланылган планы; 3. күз алдындагы предметларның урнашу тәртибе; *на переднем плане, на заднем плане* — алгы планда, арткы планда).

**ПЛАНЁР** *м. ав.*— планёр (моторсыз очкыч аппарат).

**ПЛАНЕРИ'ЗМ** *м., мн.* нет, *ав.*— планеризм (планерда очу спорты).

**ПЛАНЕРИ'СТ** *м.*, **ПЛАНЕРИ'СТКА** *ав.*— планерист, планеристка (планёрда очучы).

**ПЛАНЁРНЫЙ** *ав.*— планёр...-ы; планёрда очу...-ы; *планёрный спорт* — планёрда очу спорты.

**ПЛАНЕРОДРО'М** *м. ав.*— планеродром (планёрлар очып китә торган мәйданчык).

**ПЛАНЕ'Т** *м. с.-х.*— планет (рәт араларын чүп үләннәрдән чистарту коралы, культиватор).

**ПЛАНЕ'ТА** *ж.*— планета (1. *астр.* Кояш тирәсендә әйләнеп йөри һәм аннан яктылык һәм җылылык ала торган җисемнәр — Җир, Марс, Сатурн һ. б.; 2. *перен. разг. устар.* язмыш, киләчәк (берәүнең киләчәктә күрәчәкләре).

**ПЛАНЕТА'РИЙ** *м.*— планетарий (1. планеталарның һәм башка күк җисемнәренең хәрәкәтен күрсәтә торган прибор — кояш системасы моделе; 2. *тех.* күк йөзе кебек гөмбәзсыман экранда планеталарның хәрәкәтен сурәтләп бирүгә хезмәт итә торган проекцион фонарьлар системасыннан гыйбарәт катлаулы прибор; 3. шул механизм ярдәмендә планеталарның хәрәкәте күрсәтелә торган бина).

**ПЛАНЕТА'РНЫЙ** *астр.*— планетар; *планетарные туманности* — планетар томанлыклар.

**ПЛАНЕ'ТНЫЙ** *астр.*— планета...-ы; планеталар...-ы; *планетная система* — планеталар системасы.

**ПЛАНИ'ДА** *ж. простореч. устар.*— язмыш, киләчәк.

**ПЛАНИМЕ'ТР** *м. геодез.*— планиметр (сызымдагы мәйданнарны һәм йомык фигураларны үлчәү приборы).

**ПЛАНИМЕТРИ'ЧЕСКИЙ** — 1. *геодез.* планиметр...-ы; *планиметрические данные* — планиметр күрсәтүләре; 2. *мат.* планиметрия...-ы; *планиметрические уроки* — планиметрия дәресләре.

**ПЛАНИМЕ'ТРИЯ** *ж. мн.* нет, *мат.*— планиметрия (элементар геометриянең яссылыктагы фигураларны өйрәнә торган бүлеге).

**ПЛАНИ'РОВАНИЕ** I *ср. мн.* нет, *ав.*— к. планировать I.

**ПЛАНИ'РОВАНИЕ** II и чаще **ПЛАНИРОВА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *экон.*— планлаштыру, планын төзү, планын сызу.

**ПЛАНИ'РОВАТЬ** I *несов. ав.* — планерлау (очу аппаратында экренләп түбәнгә бару, җиргә таба төшү); *самолёт планирует* — самолёт планерлый (җиргә таба төшә).

**ПЛАНИ'РОВАТЬ** II и чаще **ПЛАНИРОВА'ТЬ** *несов.*— 1. *архит.* ... планын сызу (мәсәлән, бинаның, нинди дә булса корылманың); 2. *геодез. сад.* җир участогын бүлү, билгеләп чыгу (билгеле бер план буенча); 3. планлаштыру; *планировать производство* — производствоны планлаштыру.

**ПЛАНИ'РОВАТЬСЯ** и чаще **ПЛАНИРОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— планлаштырылу; планы сызылу; планы төзелү.

**ПЛАНИРО'ВОЧНЫЙ** *спец.*— планлаштыру...-ы; план сызу...-ы; *планировочные работы* — планлаштыру (план сызу) эшләре.

**ПЛАНИРО'ВЩИК** *м. спец.*— план төзүче, план сызучы.

**ПЛАНИСФЕ'РА** *ж. астр.*— планисфера

(җирне яки күк йөзен ярым шарлар формасында сурәтләгән карта).

**ПЛА'НКА** *ж.*— планка, юка тар такта (металлдан яки агачтан).

**ПЛАНКТО'Н** *м. биол.*— планктон (суда яшәүче һәм агым белән генә күчә алучы организмнар).

**ПЛАНКТО'ННЫЙ** *биол.*— планктон...; ***планктонные растения*** — планктон үсемлекләр; ***планктонные животные***— планктон хайваннар.

**ПЛАНОВИ'К** *м. спец.*— плановик, план төзү белгече; ***опытный плановик*** — тәҗрибәле плановик.

**ПЛА'НОВО** *нареч.*— план белән, планлы рәвештә; ***планово работать*** — планлы рәвештә эшләү, план белән эшләү.

**ПЛА'НОВО-ПРЕДУПРЕДИ'ТЕЛЬНЫЙ: планово-предупредительный ремонт** *тех.*— машиналарны тузу һәм ватылудан саклау өчен алдан үткәрелә торган ремонт (чара).

**ПЛА'НОВОСТЬ** *ж. мн.* нет.— планлы булу, планлылык; ***плановость хозяйства*** — хуҗалыкның планлылыгы.

**ПЛА'НОВЫЙ** — 1. планлы; ***плановая работа*** — планлы эш; ***плановое хозяйство*** — планлы хуҗалык; 2. планлаштыру...-ы; ***плановая комиссия*** — планлаштыру комиссиясе; 3. план...-ы, пландагы; ***плановые работы*** — пландагы эшләр.

**ПЛАНОМЕ'РНО** *нареч.*— планлы рәвештә, план белән.

**ПЛАНОМЕ'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— планлылык.

**ПЛАНОМЕ'РНЫЙ** *книж.*— 1. планлы рәвештә...; ***планомерное передвижение войск*** — гаскәрләрнең планлы рәвештә (бер урыннан икенче урынга) күчүе; 2. план буенча үткәрелә (башкарыла) торган; ***планомерные занятия*** — план буенча үткәрелә торган занятиеләр.

**ПЛАНОТВО'РЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *ирон.*— план иҗатчылыгы (кирәкмәскә мәгънәсез планнар уйлап чыгару, мәгънәсез планнар төзү белән шөгыльләнү).

**ПЛАНТА'Ж** *м. мн.* нет, *с.-х.*— плантаж (җимеш агачларын утыртканда җирне тирән итеп казу).

**ПЛАНТА'ЖНЫЙ** *с.-х.*— плантаж...-ы; ***плантажные работы*** — плантаж эшләре.

**ПЛАНТА'ТОР** *м.*— 1. плантатор, плантация хуҗасы; 2. *перен. публиц.* плантатор; ***у нас есть крепостник-плантатор, но есть и честный либерал*** (*Некрасов*)— бездә крепостник-плантатор бар, шуның белән бергә намуслы либерал да бар.

**ПЛАНТА'ТОРСКИЙ** — плантатор...-ы; плантаторлар...-ы; плантаторларча...; ***плантаторские отношения*** — плантаторларча мөнәсәбәт.

**ПЛАНТА'ТОРСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.*— плантаторлык (плантациядә эшләүче эшчеләрне эксплуатацияләү); ***жестокое плантаторство*** — рәхимсез плантаторлык.

**ПЛАНТАЦИО'ННЫЙ** *спец.*— плантация...-ы; ***плантационный каучук*** — плантация каучугы (плантациядә эшләп чыгарыла торган каучук).

**ПЛАНТА'ЦИЯ** *ж. экон.*— плантация (1. аерым культуралар җитештерә торган зур капиталистик хуҗалык; ***чайная плантация*** — чәй плантациясе; 2. аеруча җентекле тәрбия сорый торган махсус үсемлекләр чәчелгән җир участогы).

**ПЛАНША'ЙБА** *ж. тех.*— планшайба, кыстыргыч (станокта эшкәртелә торган әйберне кыстыру өчен кулланыла).

**ПЛАНШЕ'Т** *м.*— планшет (1. *порт.* корсетны кыстыру өчен металл пластинка; 2. *геодез.* план төшерү тактасы, мензуланың бер кисәге — топографик съёмкалар эшләгәндә кулланыла торган кәгазь ябыштырылган такта; 3. *геодез.* мензула ярдәмендә төшерелгән план; 4. *спец.* бер ягына квадрат сеткалы үтә күренмәле целлулоид пластинка куеп ясалган һәм карталар йөртү өчен хезмәт итә торган яссы сумка).

**ПЛАНШИ'Р** *м. мор.*— планшир (корабль бортының кырыендагы калын борыс).

**ПЛАСИРОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. спорт.*— пасирлау, пасировать итү (футбол, теннис уенында тупны каршы якта торучы тотып ала алмаслык итеп читкәрәк юнәлдерү).

**ПЛАСТ** *м.*— 1. катлам, катлау; ***пласт снега*** — кар катламы; 2. *геол.* җир катламы; 3. *с.-х.* чирәм; ***поднять пласты*** — чирәм күтәрү, чирәм сөрү. ◇ **Лежать (лечь) пластом или как пласт** *разг.*— сузылып селкенмичә яту.

**ПЛАСТА'ТЬ** *несов.*— 1. катлам-катлам итеп кисү, телем-телем итеп турау; ***пластать капусту*** — кәбестәне телем-телем итеп турау; 2. ярып эчен арчу (балыкның).

**ПЛАСТА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. катлам-катлам итеп киселү, телем-телем итеп туралу; 2. ярып эче арчылу (балыкның).

**ПЛА'СТИК** I *м. искус. устар.*— сынлы сәнгать остасы, скульптор.

**ПЛА'СТИК** II *м.*— пластик (пластик масса, үзле масса); ***пластики — превосходный изоляционный материал*** — пластиклар — бик яхшы изоляция материалы.

**ПЛА'СТИКА** *ж. мн.* нет — пластика (1. *искус.* әвәләп, кырып, коеп фигуралар ясау сәнгате; 2. шулай ясалган сәнгать әйберләре; ***музей пластики*** — пластик әйберләр музее; 3. *театр.* гәүдә белән ритмик хәрәкәтләр ясау сәнгате; ***брать уроки пластики*** — пластика дәресләре алу).

**ПЛАСТИЛИ'Н** *м. мн.* нет, *спец.*— пластилин (балавыз, цинк сабыны, сагыз, кызыл балчык, талька һәм майлы пигмент катнашмасыннан торган йомшак масса, аны төрле фигуралар ясау өчен кулланалар).

**ПЛАСТИЛИ'НОВЫЙ** — пластилин...-ы, пластилин(нан ясалган); ***пластилиновая фигурка*** — пластилиннан ясалган сын.

**ПЛАСТИ'ЛЬЩИК** *м. спец. обл.*— пластильщик, балык эчен арчучы (балык промыселларындагы махсус эшче).

**ПЛАСТИ'НА** *ж.*— 1. такта, яссы кисәк; ***железная пластина*** — тимер такта, яссы тимер кисәге; 2. *спец.* ярка бүрәнә, бүрәнәнең бер яртысы.

**ПЛАСТИ'НКА** *ж.*— пластинка; *патефонная пластинка* — патефон пластинкасы.

**ПЛАСТИ'НОЧНЫЙ** *спец.*— пластинкалы; *пластиночный фотографический аппарат* — пластинкалы фотография аппараты.

**ПЛАСТИНЧАТОЖА'БЕРНЫЕ** *ср. зоол.*— җәенке санаклылар (моллюсклар).

**ПЛАСТИНЧАТОКЛЮ'ВЫЕ** *ср. зоол.*— җәенке томшыклылар (мәсәлән, казлар, үрдәкләр).

**ПЛАСТИНЧАТОУ'СЫЕ** *ср. зоол.*— җәенке мыеклылар (коңгызларның бер төре).

**ПЛАСТИ'ЧЕСКИЙ** — 1. пластик, ритмик, сыгылма; *пластические движения* — пластик хәрәкәтләр, сыгылма хәрәкәтләр; 2. пластика...-ы; *пластическое искусство* — пластика сәнгате; 3. *мед.* пластик; *пластическая хирургия* — пластик хирургия (тәннең авырулы җиренә исән җиреннән тире алып күчереп утырту).

**ПЛАСТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. сыгылмалык, зифалык; нәфислек; *пластичность движений* — хәрәкәтләрнең сыгылмалыгы, нәфислеге; 2. йомшаклык, үзлелек; *пластичность раскалённого добела железа* — агарганчы кыздырылган тимернең үзлелеге.

**ПЛАСТИ'ЧНЫЙ** — 1. матур, зифа, салмак; 2. *спец.* сыгылма, сыгыла торган, бөгелә торган, сынмый торган, үзле; *пластичные тела* — сынмый торган җисемнәр, үзле җисемнәр.

**ПЛАСТМА'ССА** *ж.*— пластмасса (үзле масса); *изделия из пластмассы* — пластмассадан ясалган әйберләр.

**ПЛАСТОВА'ТЬ** *несов. спец.*— 1. *(накладывать пластами)* катлау-катлау итеп өю; 2. *(разделять на пласты)* катламнарга (кисү) бүлү; 3. эчен ярып арчу (балыкның).

**ПЛАСТОВА'ТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— 1. катлау-катлау итеп өелү; 2. катламнарга бүленү; 3. эче арчылу.

**ПЛАСТОВО'Й** *спец.*— катламлы; *пластовой уголь* — катламлы күмер; *пластовая горная порода* — катламлы тау токымы. ◇ **Пластовое железо** — яссы табаклы тимер.

**ПЛАСТРО'Н** *м.*— 1. пластрон (ирләр күлмәгенең куе итеп крахмалланган күкрәкчәсе); 2. *перен. устар. (о человеке)* көлкегә калган кеше, адәм көлкесе, адәм мәсхәрәсе.

**ПЛАСТУ'Н** *м.*— пластун (1. *истор.* Кубань гаскәрендә махсус командадагы җәяүле казак; 2. казак гаскәрләренең җәяүле частьларындагы казак).

**ПЛАСТУ'НСКИЙ** — пластун...-ы, пластуннар...-ы; *пластунский батальон* — пластуннар батальоны. ◇ **Ползать по-пластунски** — пластунча шуышып бару (терсәкләргә таянып).

**ПЛА'СТЫРНЫЙ** *апт. мед.* — пластырь...-ы; *пластырная масса* — пластырь массасы.

**ПЛА'СТЫРЬ** *м.*— пластырь (1. *мед. апт.* яра өстенә ябу өчен материя кисәгенә сыланган, ябышкак дару; *цинковый пластырь* — цинклы пластырь; *ртутный пластырь* — терекөмешле пластырь; 2. *мор.* судноның тишелгән урынына вакытлыча салына торган ямау).

**ПЛАТ** *м. устар.* и *ритор.*— яулык.

**ПЛА'ТА** *ж. мн.* нет — 1. түләү, түләм; *сдельная плата* — эш башыннан түләү; 2. хак; *заработная плата* — эш хакы; 3. *книж.* часто *ирон.* бүләк, әҗер; *вот плата за все мои заботы!* — менә минем барлык кайгыртуларымның әҗере!

**ПЛАТА'Н** *м. бот.*— платан (киң яфраклы бик зур агач).

**ПЛАТА'НОВЫЙ** *бот.* — платан...-ы; *платановые ветви* — платан ботаклары.

**ПЛАТА'ТЬ** *несов. порт. простореч. разг.*— ямау, ямау салу; *платать рукава* — җиңнәргә ямау салу.

**ПЛАТЁЖ** *м.*— 1. *(действие)* түләү, бурыч түләү; 2. *(то, что уплочено)* түләнгән акча.

**ПЛАТЁЖЕСПОСО'БНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *экон. торг.*— түли алучылык, түли алу сәләте, түләргә хәл житүчелек.

**ПЛАТЁЖЕСПО'СОБНЫЙ** *экон. торг.*— 1. түләүгә сәләтле; *платёжеспособное предприятие* — вакытында түләүгә сәләтле предприятие; 2. сатып алырга сәләтле.

**ПЛАТЁЖНЫЙ** *экон. фин. торг.*— түләү...-ы; түләм...-ы; *платёжная ведомость* — түләү ведомосте; *платёжное обязательство* — түләү йөкләмәсе.

**ПЛА'ТЕЛЬНЫЙ** *спец.*— күлмәклек...; *плательная ткань* — күлмәклек тукыма.

**ПЛАТЕ'ЛЬЩИК** *м.*, **ПЛАТЕ'ЛЬЩИЦА** *ж. офиц.*— түләүче.

**ПЛА'ТИНА** *ж. мн.* нет — платина, ак алтын; *самородная платина* — табигый платина; *чистая платина* — саф платина.

**ПЛАТИНА'Т** *м. хим.*— платинат (платина кислотасы тозы).

**ПЛАТИНИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. хим. тех.*— платиналау, платина йөгертү.

**ПЛАТИНИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. хим. тех.*— платиналану, платина йөгертелү.

**ПЛА'ТИННЫЙ** и чаще **ПЛА'ТИНОВЫЙ** — 1. платина...-ы; *платиновая руда* — платина рудасы; 2. платинасыман; *платиновые металлы* — платинасыман металлар; 3. платина (дан ясалган); *платиновые изделия* — платинадан ясалган әйберләр.

**ПЛАТИНОТИ'ПИЯ** *ж. мн.* нет, *спец.*— платинотипия (платина тозлары ярдәмендә фоторәсемгә төшерү ысулы).

**ПЛАТИ'ТЬ** *несов.*— 1. түләү; *платить деньги* — акча түләү; 2. *перен.* кайтару, түләү; *платить услугой за услугу* — булышлык өчен булышлык белән кайтару.

**ПЛАТИ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— түләнү; *налоги платятся в рассрочку* — салымнар срокларга бүленеп түләнә. ◇ **Платиться здоровьем за неосторожность** *разг.*— саксызлык аркасында саулыгыңны югалту.

**ПЛАТКО'ВЫЙ** *спец.*— яулыклык...; яулык...-ы; *платковый материал* — яулыклык материал.

**ПЛА'ТНЫЙ** — 1. түләүле; *платное лечение* — түләүле дәвалау; *платная должность* — түләүле хезмәт урыны; 2. акча түли

торган; *платный пассажир* — акча түли торган пассажир.

**ПЛАТО'** *ср.*— плато (1. *геогр.* өсте тигез яки дулкынлы булган шактый зур калкулык; 2. кырыйлары бөгелмәгән түгәрәк поднос).

**ПЛАТО'К** *м.*— яулык. ◇ **Носовой платок** — кульяулык.

**ПЛАТОНИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *филос.*— платонизм, платончылык (борынгы грек философы идеалист Платон — Әфләтун фәлсәфәсе. Бу фәлсәфәнең төп пункты — мәңгелек һәм үзгәрмәүчән идеяләр чынбарлыкны тәшкил итә, ә үзгәрүчән әйберләр дөньясы фәкать идеяләр дөньясының шәүләсе генә дигән караштан гыйбарәт).

**ПЛАТО'НИК** *м. филос.*— платоник, платончы (Платон шәкерте, платонизм тарафдары).

**ПЛАТОНИ'ЧЕСКИЙ** *книж.*— 1. платонизм...-ы; *платоническое учение* — платонизм өйрәтмәсе; 2. *перен. шутл.* или *ирон.* платоник, чынбарлыкта булмаган, идеядә (хыялда) гына булган, ирешә алмаслык; *платонический интерес* — платоник интерес; *платонические мечты* — ирешә алмаслык хыяллар. ◇ **Платоническая любовь** — платоник мәхәббәт (дәртлелекнең берниндн дә катнашы булмаган рухи мәхәббәт).

**ПЛАТО'ЧНЫЙ** *спец.*— яулыклык...; яулык...-ы; *платочный материал* — яулыклык материал.

**ПЛАТФО'РМА** I *ж. ж-д.*— платформа (1. поезд килеп туктый торган урында рельс буйлап ясалган калку мәйданчык; *поезд уходит с платформы № 3* — поезд 3 нче платформадан китә; 2. кечкенә генә тимер юл станциясе; *дальние поезда на платформах не останавливаются* — ерак юл поездлары кечкенә станцияләрдә туктамыйлар; 3. стенасыз һәм түшәмсез товар вагоны).

**ПЛАТФО'РМА** II *перен. книж. полит.*— платформа (берәр политик партиянең яки группаның үз өстенә алган төп политик бурычлары, таләпләре).

**ПЛА'ТЬЕ** *ср.*— 1. күлмәк (хатын-кызларда); *шёлковое платье* — ефәк күлмәк; *летнее платье* — җәйге күлмәк; 2. (өске) кием; *мужское платье* — ирләр киеме.

**ПЛАТЬЕВЩИ'ЦА** *ж.*— күлмәк тегүче.

**ПЛА'ТЬИЦЕ** *ср. разг.*— күлмәкчек, күлмәк.

**ПЛА'ТЬИШКО** *ср. разг.*— начар күлмәк, алама күлмәк.

**ПЛАТЯНО'Й** — 1. кием...-ы; киемнәр...-ы; *платяной шкаф* — кием шкафы; 2. кием...-ы, кием чистарта торган; *платяная щётка* — кием чистарта торган щётка.

**ПЛАУ'Н** *м.*— 1. *бот. (растение)* бака ефәге, су мүге, су үсемлеге; 2. (йомшак сүсле) житен сорты.

**ПЛАФО'Н** *м.*— 1. *архит. искус.* плафон, бизәкле түшәм; 2. *спец.* плафон (түшәмгә эленгән лампалар өчен ярымшар формасындагы абажур).

**ПЛА'ХА** *ж.*— 1. *обл.* ярка (икегә ярылган бүрәнә кисәге); 2. *истор.* плаха (үлем җәзасына хөкем ителгән кешенең башын салып чаба торган юан тумран); 3. *перен. поэт.* үлем җәзасы, плаха; *трон ждёт тебя.— А если плаха? (Пушкин)* — сине тәхет көтә.— Ә плаха булса?

**ПЛА'ХТА** *ж. спец.*— плахта, Украина алачасы.

**ПЛАЦ** *м. воен. истор.*— плац (парадлар һәм хәрби занятиеләр үткәрү мәйданы).

**ПЛАЦДА'РМ** *м.*— плацдарм (1. *воен.* теге яки бу стратегик операцияләр бара торган урын; 2. *перен. полит.* теге яки бу илгә каршы һөҗүм итүдә, сугыш алып баруда башлангыч чыганак пункт була алырлык территория).

**ПЛАЦЕ'НТА** *ж. анат.*— соңгылык, бала чүбе (сыер чүбе һ. б.).

**ПЛАЦЕНТА'РНЫЙ** *анат. мед.*— соңгылыклы; *плацентарные млекопитающие* — соңгылыклы имезүчеләр.

**ПЛАЦКА'РТА** *ж. ж.-д.*— плацкарт (тимер юл вагонында билгеле бер урын алу өчен билетка өстәп бирелә торган карточка; *билет с плацкартой* — плацкартлы билет; *плацкартное место* — плацкарт урын).

**ПЛАЦКА'РТНЫЙ** *ж.-д.*— плацкарт...; плацкартлы; *плацкартный вагон* — плацкарт вагон; *плацкартный билет* — плацкартлы билет.

**ПЛАЦ-ПАРА'Д** *м. воен. истор.* — к. плац.

**ПЛАЧ** *м.*— 1. елау (үксеп-үксеп елау, кычкырып елау һ. б.); 2. *этногр.* йола җыры (туйда, кеше үлгәндә, үлгән кешене искә алганда җырлана торган аянычлы җыр).

**ПЛАЧЕ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет — аянычлык, кызганычлык; *плачевность положения* — хәлнең аянычлыгы.

**ПЛАЧЕ'ВНЫЙ** — 1. аяныч, кызганыч, кызганычлы; *плачевный голос* — аяныч тавыш; *плачевное состояние* — кызганыч хәл; *плачевный вид* — кызганыч кыяфәт; 2. *перен.* әһәмиятсез, күңелсез, кызганыч; *плачевные результаты* — кызганыч нәтиҗәләр.

**ПЛАЧЕВО'Й** — йола...-ы; *плачевые песни* — йола җырлары.

**ПЛАЧЕЯ'** *ж. обл.*— к. плакальщица, плакуша.

**ПЛА'ЧИВАТЬ** *несов. простореч.*— түләштергәләү; *плачивал и дороже* — кыйммәтрәк тә түләштергәләдем.

**ПЛА'ЧУЩИЙ** — 1. елаучы; *плачущий человек* — елаучы кеше; 2. елак, кызганыч; *Дашенька!— сказал он плачущим голосом (Чехов)* — Дашенька!— диде ул елак тавыш белән.

**ПЛА'ШКА** *ж.* — 1. *обл.* к. плаха I; 2. *охот.* (*ловушка*) капкын, тәбе (вак җәнлекләрне аулый торган); 3. *тех.* сырлагыч (металл винтларга сыр ясый торган инструмент).

**ПЛАШКО'УТ** *м. мор.*— плашкоут (яссы төпле зур көймә).

**ПЛАШКО'УТНЫЙ** *мор.*— плашкоутлардан ясалган; *плашкоутный мост* — плашкоутлардан ясалган күпер.

**ПЛАШМЯ'** *нареч.*— киң ягы белән, яссы

ягы белән... (кыры, кабыргасы белән түгел); *упасть плашмя* — арка белән (яки күкрәк белән) егылу; *ударить шашкой плашмя* — кылычның яссы ягы белән сугу.

**ПЛАЩ** *м.*— плащ (1. җилкәгә салына торган җиңсез өс киеме; 2. су үткәрми торган кием).

**ПЛАЩ-ПАЛА'ТКА** *ж.* — плащ-палатка (бер үк вакытта плащ та, чатыр да булып хезмәт итә).

**ПЛЕБЕ'Й** *м.*— плебей (1. *истор.* борынгы Римда — кол булмаган, ирекле, башта гражданлык хокукыннан һәм политик хокуктан мәхрүм ителгән түбән катлау кешесе; патрицийның киресе; 2. *устар.* түбән сыйныф, „кара халык“ кешесе).

**ПЛЕБЕ'ЙСКИЙ** — плебейлар...-ы; плебейларча...; *плебейское восстание* — плебейлар восстаниесе.

**ПЛЕБЕ'ЙСТВО** *ср. мн.* нет, *устар.*— плебейлык, плебейчылык (буржуа-дворяннар телендә — „кара халык“, „кара халыкча“ уйлау, үз-үзеңне „кара халыкча“ тоту).

**ПЛЕБИСЦИ'Т** *м. полит.* — плебисцит (аеруча әһәмиятле булган зур бер мәсьәләне хәл итәр өчен бер дәүләттәге бөтен халыкның тавыш бирүе, референдум).

**ПЛЕБИСЦИТА'РНЫЙ** и **ПЛЕБИСЦИ'ТНЫЙ** *полит.*— плебисцитар...; *плебисцит белән...; плебисцитное решение вопроса* — мәсьәләне плебисцит белән хәл кылу; *плебисцитарная область* — плебисцитар өлкә (кайсы дәүләткә карарга тиешлеге плебисцит белән хәл кылынырга тиешле өлкә).

**ПЛЕБС** *м. мн.* нет — к. плебей.

**ПЛЕВА'** *ж.*— пәрдә, яры (кеше хайван, үсемлек организмнарында); *лёгочная плева* — үпкә пәрдәсе.

**ПЛЕВА'ЛЬНИЦА** и **ПЛЕВА'ТЕЛЬНИЦА** *ж.*— төкерек савыты.

**ПЛЕВА'ТЬ** *несов.*— 1. төкерү; 2. *перен. простореч. вульг.* төкерү, төкереп карау, әһәмият бирмәү, кимсетеп карау; *он плюёт на все приличия* — төкерә ул барлык әдәпләргә. ◇ **Плевать в потолок** *разг. фам.*— тушәмгә төкереп яту (берни эшләмәү).

**ПЛЕВА'ТЬСЯ** *несов. разг.*— 1. төкеренеп тору, төкеренү; 2. төкерек чәчеп сөйләү; 3. *перен разг.* төкеренү, ошатмау; *не нравится ему, всё плюётся* — ошамый аңа — һаман төкеренә.

**ПЛЕ'ВЕЛ** *м. книж.*— тиле бодай (чүп үлән).

**ПЛЕВО'К** *м.*— төкерек. ◇ **Плевка не стоит** *разг. фам. презрит.*— бер тиен тормый, бөтенләй әһәмиятсез.

**ПЛЕ'ВРА** *ж. анат.*— үпкә ярысы, үпкә пәрдәсе.

**ПЛЕВРИ'Т** *м. мн.* нет, *мед.*— плеврит (үпкә ярысы ялкынсынуы).

**ПЛЕВРИ'ТНЫЙ** *мед.*— плевриттан...; плеврит...-ы; *плевритный кашель* — плеврит ютәле, плевриттан йөткерү.

**ПЛЁВЫЙ** *простореч. фам.*— 1. әһәмиятсез, берничә яраксыз; *плёвый человек* — берничә яраксыз кеше; бер тиенгә яраксыз кеше; 2. бик җиңел, ансат; *мне это плёвое дело, в полчаса сделаю* — минем өчен бу бик җиңел эш, ярты сәгатьтә эшләп ташлыйм.

**ПЛЕД** *м.*— калын шәл (гадәттә, шакмаклы һәм чуклы).

**ПЛЕЗИОЗА'ВР** *м. палеон.*— плезиозавр (борынгы чорда диңгездә яшәгән, хәзер казылмаларда гына табыла торган, озын муенлы, кечкенә башлы кәлтә).

**ПЛЕМЕННО'Й** *книж.*— 1. кабилә...-ы, кабиләчелек...-ы; *племенной быт* — кабиләчелек тормышы; 2. нәселле; *племенной бык* — нәселле үгез. ◇ **Племенные книги** *спец.*— нәселле хайваннар исемлеге (кенәгәсе).

**ПЛЕ'МЯ** *ср.*— 1. кабилә; *первобытные племена* — борынгы кабиләләр; 2. халык, милләт; 3. *устар.* нәсел, семья, токым; *племя Пожарских вымерло (Даль)* — Пожарскийлар нәселе үлеп бетте; 4. *ритор.* буын; *комсомольское племя* — комсомоллар буыны; 5. нәсел; *оставить на племя* — нәселгә калдыру. ◇ **Без роду, без племени** — илсез-йортсыз, нәсел-нәсәпсез.

**ПЛЕМЯ'ННИК** *м.*— бертуган кардәшнең улы; *родной племянник* — бертуганның улы; *двоюродный племянник* — энисе яки этисе белән бертуганның баласының улы.

**ПЛЕМЯ'ННИЦА** *ж.* — бертуган кардәшнең кызы.

**ПЛЕМЯ'Ш** *м. простореч. фам.*— к. племянник.

**ПЛЕН** *м. мн.* нет — 1. плен, әсирлек, тоткынлык; *взять в плен* — пленга алу; *попасть в плен* — пленга төшү, плен төшү, әсирлеккә төшү; *убежать из плена* — пленнан качу, әсирлектән качу; 2. *перен. книж.* бәйлелек, боендырык (политик-экономик, иҗтимагый яктан, идея, психология ягыннан); *освободиться от плена предрассудков* — хорафатлар боендырыгыннан котылу.

**ПЛЕНА'** *ж.*— 1. *устар.* к. плёнка 1; 2.*обл. спец.* ялтыравык катлам (таш яки металл эчендә).

**ПЛЕНА'РНЫЙ** *офиц.* — пленар, гомуми (утырышлар турында).

**ПЛЕНЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж. устар.*— 1. *воен.* пленга, әсирлеккә алу; 2. к. плен 1.

**ПЛЕНИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж. поэт.*— сокландыргыч булу.

**ПЛЕНИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж. поэт.*— сокландыргыч, сокланырлык, сихерләгеч, гаҗәп матур, бик кызыктыргыч.

**ПЛЕНИ'ТЬ** *сов. книж.*— 1. *устар.* пленга алу, әсир итү; 2. *устар.* яулап алу, буйсындыру; 3. *перен.* әсир итү, сокландыру, үзенә тарту; *пленить кого-нибудь своим умом, своей красотой* — үзенең акылын, матурлыгын белән кемне дә булса үзенә әсир итү.

**ПЛЕНИ'ТЬСЯ** *сов. книж.*— әсир булу, соклану; *плениться чьей-либо красотой* — кемнең дә булса матурлыгына соклану.

**ПЛЁНКА** *ж.*—1. элпә, яры; 2. плёнка (фотография эшендә һәм киносъёмкада кулланыла).

**ПЛЕ'ННИК** *м.*, **ПЛЕ'ННИЦА** *ж. книж.*— 1. әсир, тоткын, пленга төшкән кеше, плендагы кеше, тоткынлыкка төшкән кеше; 2. *перен. поэт.* әсир, әсир булган кеше, бирелгән кеше (берәр нәрсәгә); *пленник собственных страстей* — үз дәртләренең әсире, үз дәртләренә бирелгән кеше.

**ПЛЕ'ННЫЙ** — 1. плендагы кеше, әсир, пленга эләккән, пленга төшкән кеше; пленный; *прибыла новая партия пленных* — пленныйларның яңа партиясе килде; 2. *перен. книж.* әсир ителгән, бирелгән, буйсынган.

**ПЛЁНОЧНЫЙ** *спец.*— плёнкалы; *плёночный фотоаппарат*—плёнкалы фотоаппарат.

**ПЛЕ'НУМ** *м. офиц.*— пленум (нинди дә булса оешманың тулы составы белән булган җыелышы); *расширенный пленум* — киңәйтелгән пленум (махсус чакырылган кешеләр катнашы белән булган җыелыш).

**ПЛЕНЯ'ТЬ** *несов. книж.*— 1. *устар.* к. пленить; 2. сокландыргыч булу, сокландыру, үзенә әсир итү; *всё в ней пленяло* — аның бар ягы да сокландыргыч иде.

**ПЛЕНЯ'ТЬСЯ** *несов. книж.* — к. плениться.

**ПЛЕОНА'ЗМ** *м. лит.*— плеоназм (мәгънәдәш сүзләрдән, тәгъбирләрдән гыйбарәт булган сөйләм әйләнмәсе, мәсәлән: *спор был долгий и продолжительный* — бәхәс озак һәм дәвамлы булды).

**ПЛЕОНАСТИ'ЧЕСКИЙ** *лит.*— плеоназмлы; *плеонастический стиль* — плеоназмлы стиль.

**ПЛЕРЕ'ЗЫ** *ед.* нет, *устар.*— траур тасмасы, траур лентасы (берәр зур кайгы төшкән вакытта күлмәккә тегелеп куела торган тасма).

**ПЛЁС** *м.* — плёс (1. елгада яки күлдә утраулар арасындагы киң су мәйданы; 2. *спец.* елганың пароходлар йөри алу һәм яр кырые шартлары бердәй булган өлеше; 3. елганың бер борылышыннан икенче борылышына кадәр булган туры җире).

**ПЛЕ'СЕННЫЙ** —күгәрек...-ы; *слышен плесенный запах* — күгәрек исе килә.

**ПЛЕ'СЕНЬ** *ж.*— күгәрек; *от сырости плесень завелась* — дымлылыктан күгәрек барлыкка килгән. ◇ **Покрыться плесенью** *перен. ритор.*— картаеп бетү, какшау.

**ПЛЕ'СК** *м.*— 1. *только ед.* су чайкалуы, дулкын тавышы; *плеск ночной волны* — төнге дулкын тавышы; 2. *устар.* кул чабу; 3. *обл.* и *спец.* балык койрыгы.

**ПЛЕСКА'ТЬ** *несов. разг.*— 1. чайкалып китереп бәрү; *волны плещут о борт корабля* — дулкыннар чайкалып корабль бортына китереп бәрәләр; 2. чайкалдыру; *плескать вёслами по воде* — ишкәкләр белән суны чайкалдыру; 3. су чәчрәтү; *мальчишки, купаясь, плещут друг на дружку* — малайлар коенганда бер-беренә су чәчрәтәләр; 4. *перен. книж. поэт.* җилфердәү; *тихо плещут паруса* — җилкәннәр әкрен генә җилфердиләр; 5. *устар.* кул чабу.

**ПЛЕСКА'ТЬСЯ** *несов. разг.*— 1. чайкалып килеп бәрелү; *волны плещутся о берег* — дулкыннар чайкалып яр кырыена килеп бәреләләр; 2. су чәчрәтү; *ребёнок плескается в ванне* — бала ваннада су чәчрәтеп утыра; 3. су чәчрәтешү; *мальчики плескаются в реке* — малайлар елгада су чәчрәтешәләр; 4. *перен. книж. поэт.* җилфердәү; *в прозрачном воздухе плещутся флаги* — саф һавада флаглар җилфердиләр.

**ПЛЕ'СНЕВЕТЬ** *несов.* — күгәрү, күксү; *хлеб от сырости плесневеет* — икмәк юешлектән күгәрә (күкси).

**ПЛЕСНЕВИ'ЦА** *ж. мн.* нет, *мед.*— гөмбә (имчәк балаларында авыз бозылу авыруы).

**ПЛЕСНЕВО'Й** *спец.*— күгәрек...-ы; *плесневой грибок* — күгәрек гөмбәсе.

**ПЛЕ'СНЕТЬ** *несов. простореч.*— к. плесневеть.

**ПЛЕСНУ'ТЬ** *сов.*— суга бәреп алу; *рыбка хвостом по воде плеснула* — балык койрыгы белән суга бәреп алды.

**ПЛЕСТИ'** *несов.*— 1. үрү; *плести корзину* — кәрзин үрү; *плести венки* — венок үрү; *плести лапти* — чабата үрү; 2. бәйләү; *плести кружева* — челтәр бәйләү; 3. *перен.* тудыру, китереп чыгару; *плести интригу* — интрига китереп чыгару; 4. *перен. разг. пренебр.* әвәләп чыгару (шигырь, әсәр); 5. *разг. фам.* акылсыз сүз сөйләү, такылдау, акылга сыймаслык нәрсә әйтү; *что ты там плетёшь?*— нәрсә син анда такылдыйсың? *плести чушь* — буш сүз сөйләү; 6. *разг.* ялганлау, ялган сүз сөйләү, гайбәт сөйләү, гайбәт сату; *плести небылицы на кого-нибудь* — берәр кеше турында юк-бар нәрсә сөйләү.

**ПЛЕСТИ'СЬ** *несов.* — 1. *страд.* үрелү; 2.*страд.* бәйләнү; *кружева плетутся разными способами* — челтәр төрлечә бәйләнә; 3. *разг.* көчкә-көчкә бару, көч-хәл белән бару; әкрен генә атлап бару. ◇ **Плестись в хвосте** — койрыкта сөйрәлү.

**ПЛЕТЕ'ЙНЫЙ** *спец.*—бәйләү...-ы; *плетейная игла* — бәйләү энәсе.

**ПЛЕТЕ'ЛЬЩИК** *м.*, **ПЛЕТЕ'ЛЬЩИЦА** *ж. спец.*— үрүче, бәйләүче, үреп ясаучы, үрү остасы.

**ПЛЕТЕ'НИЕ** *ср.*—1. *(действие)* үрү, үреп ясау; бәйләү; 2. үреп ясалган әйбер. ◇ **Плетение словес** *лит. ирон.*— сүз боткасы.

**ПЛЕТЁНКА** *ж. обл.* и *спец.*— 1. үреп ясалган әйбер; 2. *(витой хлеб)* үреп пешерелгән булка.

**ПЛЕТЁНЫЙ** — үрелгән, үреп ясалган, үргән; *плетёная мебель* — үргән мебель.

**ПЛЕТЕ'НЬ** *м.*— читән (чыбыктан үреп ясалган тәбәнәк киртә).

**ПЛЁТКА** *ж.*— кыска камчы.

**ПЛЕТНЁВЫЙ** *спец.*— читән...; *плетнёвые заграждения* — читән киртәләр.

**ПЛЕТЬ** *ж.*— 1. камчы; 2. үрелмә сабак (колмак, кыяр, кабак сабагы). ◇ **Плетью обуха не перешибёшь** — к. перешибить.

**ПЛЕЧЕВО'Й** *анат.* — иңбаш...-ы; кулбаш...-ы; *плечевая кость* — кулбаш сөяге; *плечевой сустав* — иңбаш буыны.

**ПЛЕ'ЧИКИ** *мн. разг.* — киерге, күлмәк элгеч, пальто элгеч; *надеть платье на плечики* — күлмәкне киергегә элү.

**ПЛЕ'ЧИКО** *ср. разг.*— 1. инбаш; 2. *спец.* эчке күлмәк бавы; *спустить плечико* — эчке күлмәкнең бавын бушайта төшү.

**ПЛЕЧИ'СТЫЙ** — киң кулбашлы, киң җилкәле; *плечистый парень*—киң җилкәле егет.

**ПЛЕЧО'** *ср.*— 1. инбаш, кулбаш; 2. *физ.* инсә (мәсәлән, үлчәү көянтәсенең яртысы). ◇ **Плечом к плечу идти** — рәттән бару, янәшә бару; бердәм атлау. **(Словно) гора с плеч свалилась** — җилкәмнән тау төшкән кебек булды. **С плеч долой** — эше бетте, вәссәләм. **С плеча** — 1. кискен рәвештә; 2. уйламыйча; ничек җитте алай; *этот вопрос нельзя решать с плеча* — бу мәсьәләне ничек җитте алай чишәргә ярамый. **Не по плечу** *разг.*— көч җитми, көч җитәрлек түгел; *мне эта работа не по плечу* — бу эшкә минем көчем җитми. **Выносить на своих плечах** — үз җилкәндә күтәрү, үз өстеңә алу. **Иметь голову на плечах** *разг.* — уйлап, аңлап эш итү. **За плечами иметь** *разг.*—кичерү, баштан үткәрү; *у него за плечами 60 лет трудовой жизни* — ул 60 еллык хезмәт гомере кичергән, аның 60 еллык хезмәт гомере бар. **Каждому на плечах голова люба** — һәркемнең үз башы җәл, һәркемнең үз башы кадерле. **Плечами пожимать** — гаҗәпләнү, ис китү, инбашларын җыеру. **На плечах противника** *воен.*— чигенә торган дошман артыннан калмыйча (бару).

**ПЛЕШИ'ВЕТЬ** *несов.*— пеләшләнү, чәчсез калу.

**ПЛЕШИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — пеләшлек.

**ПЛЕШИ'ВЫЙ** — пеләш, пеләш башлы; *плешивая голова* — пеләш баш.

**ПЛЕШИ'НА** *ж.*— 1. *обл.* пеләш, чәч коелган урын, йон коелган урын; *плешина на спине у собаки* — этнең аркасында йоны коелган урын; *плешина на меховом воротнике* — мех якада йоны кырылган урын (мех яканың кырылган урыны); 2. үсемлексез урын (урманда, тау түбәсендә, иген басуында, болында).

**ПЛЕШЬ** *ж.*— к. плешина.

**ПЛЕЯ'ДА** *ж. книж.*— плеяда (1. бер үк өлкәдә, бер үк юнәлештә эшләп атказанган кешеләр группасы; *пушкинская плеяда* — Пушкин плеядасы; 2. *лит.* XVI йөздә Франциядә шагыйрьләр түгәрәге исеме).

**ПЛИ** *междом. воен. устар.*— ат! ут ач! (атарга, ут ачарга команда бирү сүзе).

**ПЛИНТОВА'ТЬ** *несов. спец.* — тигезләү, чистарту (түмгәкләрен бетерү); *плинтовать землю под пашню* — җирне сөрү өчен тигезләү (чистарту).

**ПЛИНТОВА'ТЬСЯ** *несов. страд. спец.* — тигезләнү, чистартылу.

**ПЛИ'НТУС** *м. архит.*— плинтус (1. стена белән идән арасындагы ярыкны каплый торган тар гына такта — планка; 2. мичнең, стенаның кинрәк итеп эшләнгән, чыгып тора торган аскы өлеше).

**ПЛИС** *м.* — плис (киҗе-мамыктан тукылган бәрхет).

**ПЛИ'СОВЫЙ** — плис...; плистан тегелгән.

**ПЛИССЕ'** *ср. нескл. спец.* — плиссе (1. материядә бер-бер артлы тезелгән һәм үтүкләнгән складкалар; 2. плисселе материя).

**ПЛИССИРОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.*— плисселәр ясау, плиссировать итү.

**ПЛИССИРОВА'ТЬСЯ** *несов. страд. спец.* — плисселәр ясалу, плиссировать ителү.

**ПЛИТА'** *ж.* — плитә (1. дүрт кырлы тигез яссы металл яки таш кисәге; 2. аш пешерү өчен металл тактасы булган кухня миче).

**ПЛИ'ТКА** I *ж. разг.* — плитка (1. кечкенә генә плитә; 2. кечкенә генә дүрт кырлы яссы кисәк); *шоколадная плитка* — шоколад плиткасы; *акварельные краски в плитках* — плиткалы акварель буяулары.

**ПЛИ'ТКА** II *ж.* — плитка (ашамлык пешерү өчен кулланыла торган электр приборы).

**ПЛИТНЯ'К** *м. мн.* нет, *спец.* — катламлы таш (такталанып аерыла һәм төзү эшләрендә кулланыла торган таш).

**ПЛИ'ТОЧНЫЙ** *спец.* — 1. плита...-ы; *плиточная форма* — плита формасы; 2. плиткалы; такта...; *плиточный шоколад* — плиткалы шоколад; *плиточный чай* — такта чәй.

**ПЛИ'ЦА** *ж. спец.* — 1. соскыч (суднода, көймәдә җыелган суны сосып бушату приборы); 2. пароход тәгәрмәченең калагы.

**ПЛОВ** *м.* — пылау.

**ПЛОВЕ'Ц** *м.* — 1. йөзүче, йөзә белүче, оста йөзүче; *опытный пловец* — тәҗрибәле йөзүче; 2. *устар. (мореплаватель)* диңгез сәяхәтчесе.

**ПЛОВЧИ'ХА** *ж. спорт.* — йөзүче (хатынкыз); *пловчиха-рекордсменка* — йөзүче-рекордсменка.

**ПЛОД** *м.* — 1. *бот.* җимеш; *односемянные плоды* — бер орлыклы җимешләр; *многосемянные плоды* — күп орлыклы җимешләр; 2. *биол. (зародыш детёныша)* карындагы бала; 3. *перен.* нәтиҗә; җимеш; *плод небрежности* — саксызлык нәтиҗәсе; *плод долголетнего труда* — күпьеллык хезмәт җимеше.

**ПЛОДИ'ТЬ** *несов.* — 1. үрчетү (бала); 2. *перен. разг. фам.* күп күләмдә барлыкка китерү (мәсәлән, күп язу); *плодить одну статью за другой* — мәкаләләрне берсе артыннан икенчесен язып кына тору.

**ПЛОДИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. үрчү; 2. *перен. книж.* килеп чыгу, барлыкка килү, туу; *от безделья плодятся сплетни и раздоры* — эшсезлектән гайбәт һәм ызгышлар туа.

**ПЛО'ДНИК** *м. бот.* — к. пестик I.

**ПЛО'ДНЫЙ** *спец.* — җимеш бирә торган; токым бирә торган; токым бирүгә сәләтле.

**ПЛОДОВИ'ТОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. үрчемлелек, тиз үрчүчәнлек; 2. күп иҗат итүчәнлек.

**ПЛОДОВИ'ТЫЙ** *книж.* — 1. күп җимеш бирә торган; 2. күп үрчемле, үрчем бирә торган, тиз үрчи торган; 3. күп иҗат итүче, күп иҗат итүчән; *плодовитый писатель* — күп иҗат итүчән язучы; 4. *перен. устар.* күп сүзле; *плодовитый слог* — күп сүзле

стиль; 5. *устар.* жимеш...-ы; *плодовитый сад* — җимеш бакчасы.

**ПЛОДОВО'Д** *м. с.-х.* — җимеш үстерүче (белгеч), бакчачы.

**ПЛОДОВО'ДСТВО** *ср. мн.* нет, *с.-х.* — җимешчелек, җимеш үстерүчелек.

**ПЛОДОВО'ДЧЕСКИЙ** *с.-х.* — җимеш үстерү...-ы; *плодоводческий совхоз* — җимеш үстерү совхозы.

**ПЛОДО'ВЫЙ** — 1. җимеш...-ы; *плодовые деревья* — җимеш агачлары; *плодовый сад* — җимеш бакчасы; 2. *спец.* җимештән ясалган; *плодовые консервы* — җимештән ясалган консерв; 3. *бот.* үрчү...-ы; *плодовое тело грибов* — гөмбәләрнең үрчү әгъзасы.

**ПЛОДОГО'ННЫЙ** *мед.* — бала төшерү...-ы; *плодогонные средства* — бала төшерү чаралары.

**ПЛОДОЖИ'Л** *м. зоол.* — җимеш коңгызы (йомыркаларын җимеш эченә сала торган корткыч).

**ПЛОДОЖО'РКА** *ж. зоол.* — җимеш күбәләге (корткыч); *яблочная плодожорка* — алма күбәләге.

**ПЛОДОИЗГНА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *мед.* — бала төшертү (карындагы баланы).

**ПЛОДОНО'ЖКА** *ж. бот.* — җимеш сабы.

**ПЛОДОНОСИ'ТЬ** *несов. спец.* — җимеш бирү, җимеш бирергә сәләтле булу; *нам удалось в комнате вырастить плодоносящее лимонное деревцо* — без бүлмәдә җимеш бирә торган лимон агачы үстерә алдык.

**ПЛОДОНО'СНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — җимеш бирүчәнлек.

**ПЛОДОНО'СНЫЙ** — җимеш бирә торган.

**ПЛОДОНОШЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *спец.* — җимеш бирү.

**ПЛОДООВОЩЕСУШИ'ЛКА** *ж. с.-х.* — к. плодосушилка.

**ПЛОДООВОЩЕСУШИ'ЛЬНЯ** *ж. с.-х.* — к. плодосушильня.

**ПЛОДООВОЩНО'Й** *с.-х.* — җимеш-яшелчә...-ы; *плодоовощное хозяйство* — җимеш-яшелчә хуҗалыгы.

**ПЛОДООВО'ЩЬ** *ж. с.-х.* — җимеш-яшелчә.

**ПЛОДОПЕРЕМЕ'ННЫЙ** *с.-х.* — к. плодосменный.

**ПЛОДОПЕРЕРАБО'ТКА** *ж. мн.* нет, *с.-х.* — җимеш эшкәртү.

**ПЛОДОРО'ДИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — уңдырыш, уңдырышлылык, уңыш бирүчәнлек, уңыш бирү.

**ПЛОДОРО'ДНЫЙ** — уңдырышлы, уңыш бирә торган, уңыш бирүчән, зур уңыш бирә торган; *плодородная почва* — уңдырышлы туфрак.

**ПЛОДОСБО'Р** *м. мн.* нет, *с.-х.* — җимеш җыю, җимеш уңышы җыю.

**ПЛОДОСМЕ'Н** *м. мн.* нет, *с.-х.* — алмаш чәчү, орлык алмашы (бер үк җиргә бер елны бер төрле, икенче елны икенче төрле үсемлек чәчү).

**ПЛОДОСМЕ'ННЫЙ** *с.-х.* — алмаш чәчү...-ы; *плодосменная система полеводства* — кырчылыкта алмаш чәчү системасы.

**ПЛОДОСНИМА'ТЕЛЬ** *м. с.-х.* — к. плодосъём.

**ПЛОДОСУШИ'ЛКА** *ж. с.-х.* — җимеш киптергеч, яшелчә киптергеч.

**ПЛОДОСУШИ'ЛЬНЯ** *ж. с.-х.* — җимеш (яшелчә) киптерү урыны.

**ПЛОДОСЪЁМ** *м. с.-х.* — җимеш өзгеч, җимеш җыйгыч (үсемлекләрдән җимеш өзеп җыю коралы).

**ПЛОДОТВО'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — уңышлылык, нәтиҗәлелек, файдалылык; *плодотворность идеи* — идеянең файдалылыгы.

**ПЛОДОТВО'РНЫЙ** *книж.* — 1. *устар.* файдалы, үсүне тизләтә торган; шифалы; *плодотворный дождь* — үсүне тизләтә торган яңгыр, шифалы яңгыр; 2. *перен.* яхшы, уңышлы; нәтиҗәле, файдалы; *плодотворные идеи* — файдалы идеяләр; *плодотворное начинание* — уңышлы адым, нәтиҗәле башланыш.

**ПЛОДОХРАНИ'ЛИЩЕ** *ср. с.-х.* — яшелчә һәм җимеш саклау урыны.

**ПЛОДУ'ХА** *ж. бот.* — җимеш бирә торган ботак.

**ПЛОДУ'ЩИЙ** *бот. с.-х.* — 1. җимеш бирә торган, җимеш бирүгә сәләтле; *плодущий побег* — җимеш бирүгә сәләтле ботак; 2. үрчем бирә торган, үрчем бирүгә сәләтле; *волки почти со всеми породами собак дают плодущие помеси* — бүреләр этләрнең барлык токымнары белән диярлек үрчем бирүгә сәләтле кушылдык бирәләр.

**ПЛОЁНЫЙ** *спец.* — 1. бөдрәләтелгән; *плоёные волосы* — бөдрәләтелгән чәч; 2. бөрмәләндерелгән; *плоёная ткань* — бөрмәләндерелгән тукыма.

**ПЛОИ'ТЬ** *несов. спец.* — 1. бөдрәләү (чәчне); 2. бөрмәләү (күлмәкне, тукыманы).

**ПЛО'МБА** *ж.* — пломба (1. товарга келәймәләнеп тагып куелган кургашын кисәге; 2. бозык тештә барлыкка килгән куышлыкны ямау материалы).

**ПЛОМБИ'Р** I *м. кулин.* — пломбир (каймак, шоколад һ. б. шундый ашамлыкларга цукат салынып туңдырылган морожный сорты).

**ПЛОМБИ'Р** II *м. спец.* — пломбир (товарга, ишекләргә пломба кую җайланмасы).

**ПЛОМБИРО'ВАННЫЙ** — пломбаланган, ямалган, пломбалы; *пломбированные зубы* — пломбаланган тешләр, пломбалы тешләр.

**ПЛОМБИРОВА'ТЬ** *несов.* — пломбалау, пломба салу, пломба сугу, пломба кую; *пломбировать товары* — товарга пломба сугу (салу); *пломбировать вагон* — вагонны пломбалау; *пломбировать зубы* — тешләрне пломбалау, тешләргә пломба кую.

**ПЛОМБИРОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — пломбалану, пломба куелу, пломба салыну, пломба сугылу.

**ПЛОМБИРО'ВЩИК** *м. спец.* — пломбалаучы, пломба салучы, пломба сугучы, пломба куючы.

**ПЛО'СКИЙ** — 1. яссы, ялпак, җәенке; *плоская поверхность* — яссы йөз, яссы өслек; *плоская стопа* — яссы табан; 2. сөзәк; *плоский лоб* — сөзәк маңгай; *плоская кры-*

*ша* — сөзәк түбә; 3. сай; *плоская тарелка* — сай тәлинкә; 4. *перен.* оятсыз, эшәке, тупас; *плоская шутка* — тупас шаярту.

**ПЛОСКОГО'РЬЕ** *ср. геогр.* — яссы таулык, яссы калку урын (җир йөзендә).

**ПЛОСКОГРУ'ДЫЙ** — яссы күкрәкле, такта күкрәкле; *плоскогрудая девушка* — такта күкрәкле кыз.

**ПЛОСКОГУ'БЦЫ** *ед.* нет, *спец.* — яссы карга борыны, яссы борынлы кыскыч.

**ПЛОСКОДО'НКА** *ж.* — яссы төпле көймә.

**ПЛОСКОДО'ННЫЙ** — яссы төпле (мәсәлән, баркас, көймә).

**ПЛОСКОСТО'ПИЕ** *ср. мн.* нет, *мед.* — яссы табанлылык; *плоскостопие—профессиональная болезнь людей, работающих стоя* — яссы табанлылык — аягүрә эшләүчеләрнең профессиональ авыруы.

**ПЛО'СКОСТЬ** *ж.* — 1. *мат.* яссылык; *пересечение плоскостей* — яссылыкларның кисешүе; 2. *перен. книж.* өлкә, сфера, тармак; *эти вопросы лежат в разных плоскостях* — бу мәсьәләләр төрле өлкәгә карыйлар; 3. тупас мәзәк, оятсыз мәзәк; *говорить плоскости* — тупас мәзәкләр сөйләү, оятсыз мәзәкләр сөйләү. ◇ **По наклонной плоскости (пойти, кататься)** *перен.* — (политик, экономик яктан яки мораль һәм әхлак ягыннан) түбәнгә таба (бару, тәгәрәү, төшү).

**ПЛО'СЧЕ** — яссырак.

**ПЛОТ** *м.* — 1. сал (суда агызу өчен бер яки берничә рәт итеп беркетелгән бүрәнәләр); 2. басма (кер чайкау һ. б. өчен).

**ПЛОТВА'** *ж. мн.* нет, *зоол.* — чабак (балык).

**ПЛО'ТИК** I *м.* — 1. кечкенә сал; 2. кечкенә басма.

**ПЛО'ТИК** II *м. горн.* — плотик (руда юу өчен хезмәт итә торган җайланма, улак).

**ПЛОТИ'ЛЬЩИК** *м. спец.* — сал бәйләүче.

**ПЛОТИ'НА** *ж.* — 1. буа, бөя; 2. *перен.* каршылык, киртә, комачау; *создать плотину против военной опасности* — сугыш куркынычына каршы киртә салу.

**ПЛОТИ'ННЫЙ** *спец.* — буа...-ы; *плотинный затвор* — буа япкычы.

**ПЛОТИ'ТЬ** *несов. спец.* — (бүрәнәләрне, такталарны) тезеп беркетү, тезеп җаю. ◇ **Плотить плоты** — сал саллау.

**ПЛОТИ'ЦА** и чаще **ПЛОТИ'ЧКА** *ж.* — к. плотва.

**ПЛОТНЕ'ТЬ** *несов.* — 1. ныгу, тыгызлану; 2. тазару.

**ПЛО'ТНИК** *м.* — балта остасы, плотник.

**ПЛОТНИ'ТЬ** *несов. спец.* — ныгыту, тыгызландыру.

**ПЛО'ТНИЧАТЬ** *несов.* — балта остасы булып эшләү, балта эшләре белән шөгыльләнү.

**ПЛО'ТНИЧЕСКИЙ** — балта остасы...-ы; балта осталары...-ы; *плотнический инструмент* — балта остасы инструменты; *плотничья артель* — балта осталары артеле.

**ПЛО'ТНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.* — балта эшләре, плотниклык; *заниматься плотничеством* — балта эшләре белән шөгыльләнү.

**ПЛО'ТНИЧИЙ** — к. плотнический.

**ПЛО'ТНИЧНЫЙ** *спец.* — балта остасы...-ы; *плотничные инструменты* — балта остасы инструментлары.

**ПЛО'ТНО** *нареч.* — 1. нык итеп, тыгыз итеп; *плотно заколотить дверь* — ишекне нык итеп кагып кую; 2. янәшә, бик якын китереп, терәп; *приставить шкаф плотно к стене* — шкафны стенага терәп кую.

**ПЛО'ТНОСТЬ** *ж.* — тыгызлык, ныклык, куелык; *плотность населения* — халыкның тыгызлыгы; *плотность ткани* — тукыманың ныклыгы; *плотность огня* (*воен.*) — ату(ның) куелыгы.

**ПЛО'ТНЫЙ** — 1. нык, тыгыз, еш, куе; *плотная масса* — куе масса; *плотный газ* — куе газ; *ткань плотного переплетения* — еш тукыма, тыгыз тукыма; *плотно набитый бумажник* — тыгызлап тутырылган бумажник; 2. *разг.* таза (гәүдәгә карата); *за кухонным столом сидел большой плотный мужик* (*Чехов*) — кухня өстәле янында зур таза гәүдәле мужик утыра иде; 3. *разг.* туклыклы, яхшы; *плотный обед* — туклыклы төшке аш.

**ПЛОТОВО'Д** *м. спец.* — 1. сал агызучы; 2. сал тартучы (пароход).

**ПЛОТОВО'Й** *спец. обл.* — сал белән агызыла торган; *плотовой лес* — сал белән агызыла торган агач материалы.

**ПЛОТОВЩИ'К** *м. спец. обл.* — салчы (1. сал саллау һәм аны агызу эшчесе; 2. пассажирларны сал һәм паром белән елга аркылы чыгаручы, паромчы).

**ПЛОТОГО'Н** *м. спец. обл.* — сал озатучы, сал куучы (салны агызып җибәрүче һәм озатып баручы).

**ПЛОТОСПУ'СК** *м. тех.* — сал уздыру капкасы (буада).

**ПЛОТОЯ'ДНО** *нареч.* — йотардай булып, күзен майландырып; *плотоядно смотрел на свою жертву* — үзенең корбанына йотардай булып карый иде.

**ПЛОТОЯ'ДНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. *зоол.* ерткычлык, ит белән туенучылык; 2. *бот.* бөҗәк ашаучылык, бөҗәкләр белән туенучылык; 3. *перен. книж.* хайвани теләк булу, җенси теләк булу.

**ПЛОТОЯ'ДНЫЙ** — 1. *зоол.* ерткыч, ит белән туенучы; 2. *бот.* бөҗәк белән туенучы, бөҗәк ашаучы; 3. *перен. книж.* хайвани (җенси) теләкле; *плотоядная улыбка* — җенси теләкле елмаю.

**ПЛО'ТСКИЙ** *книж. устар.* и *церк.* — тән...-ы; җенси, хайвани; *плотские интересы* — җенси теләк, хайвани интереслар; *плотские инстинкты* — җенси инстинктлар.

**ПЛОТЬ** *ж. мн.* нет — 1. *книж. устар.* и *церк.* — тән; *немощная плоть* — зәгыйфь тән; 2. *книж. устар.* и *церк.* җенси теләк, хайвани тойгы; *умерщвлять плоть* — хайвани тойгыны юк итү; *смирить свою плоть* — үзеңнең хайвани тойгыларына юл куймау; 3. *устар.* и *обл.* (*мужское семя*) ир орлыгы, сперматозоид; 4. *обл.* (*перхоть*) кавык, кубык (башта була). ◇ **Плоть и кровь** — к. кровь. **Плоть от плоти, кость от кости** *чьей* **или плоть**

и кровь *чья (книж. ритор.)* — үз каны (м, н), үз баласы (үз балам, үз балан).

**ПЛО'ХЕНЬКИЙ** — к. плохонький.

**ПЛО'ХО** — 1. *нареч.* начар; *написано из рук вон плохо* — бик начар язылган; 2. *в знач. сущ. нескл.* начар билгесе (мәктәптә балаларның белемнәрен бәяләгәндә куела торган түбән билге); *получил плохо по физике* — физикадан начар билгесе алдым.

**ПЛОХОВА'ТО** *нареч. в знач. сказ.* — бик үк яхшыдан түгел; *здоровье плоховато* — исәнлек бик үк яхшыдан түгел; *дела идут плоховато* — эшләр бик үк яхшыдан түгел.

**ПЛОХОВА'ТЫЙ** *разг.* — начаррак.

**ПЛОХО'Й** — начар, алама, кәй, койты; *плохой товар* — начар товар. ◇ **Плохо лежит** *разг.* — яшерен куелмаган (урларга мөмкин). **Кончить плохо или плохим** *разг.* — уңышсызлыкка очрау, бәхетсезлеккә очрау, начар килеп чыгу; *он кончит плохо* — аның эше яхшыга барып чыкмас. **Плохо-плохо** *разг.* — аз дигәндә; *он плохо-плохо тысячу рублей в месяц зарабатывает* — ул аз дигәндә айга мең сум эшли. **Шутки плохи** *перен.* — шаярырга ярамый, шаяру урынсыз, шаяру яхшылыкка булмас.

**ПЛО'ХОНЬКИЙ** *разг.* — начар гына.

**ПЛОША'ТЬ** *несов.* — 1. *разг. фам.* ялгышу, хата җибәрү (берәр эштә); 2. *обл.* начарлана бару; *здоровье плошает* — сәламәтлек начарлана бара.

**ПЛО'ШЕ** — начаррак.

**ПЛО'ШКА** *ж.* — 1. *обл.* сай савыт, сай тәлинкә; 2. *истор.* кечкенә шәмдәл.

**ПЛОЩА'ДКА** *ж.* — 1. мәйданчык; *детская площадка* — балалар мәйданчыгы; *площадка для посадки самолётов* — самолётлар төшү мәйданчыгы; 2. площадка; *площадка на лестнице* — баскычтагы площадка.

**ПЛОЩАДНО'Й** — тупас, әшәке, әдәпсез, урам...-ы; *площадная брань* — тупас сүзләр, урам сүзләре.

**ПЛО'ЩАДЬ** *ж.* — мәйдан; *площадь посева* — чәчү мәйданы; *площадь прямоугольника* — туры почмакның мәйданы.

**ПЛО'ЩЕ** — к. плосче.

**ПЛУГ** *м.* — сабан; *пахать плугом* — сабан белән сөрү.

**ПЛУГА'РЬ, ПЛУГАТА'РЬ, ПЛУГА'ТОР** *м.* — 1. *устар.* сабанчы (сабан белән җир сөрүче); 2. плугарь (трактор сабанында эшләүче).

**ПЛУГОВО'Й** *с.-х.* — сабан...-ы; *плуговой лемех* — сабан төрәне.

**ПЛУЖНИ'К** *м. обл.* — 1. *(лемех)* төрән; 2. *(плугарь)* сабанчы.

**ПЛУ'ЖНЫЙ** *экон.* — хайван көче белән алып барыла торган, хайван көченә нигезләнгән (игенчелек, җир эшләре).

**ПЛУ'НЖЕР** *м. тех.* — плунжер, пешкәк (суырта торган насоста озын цилиндр формасындагы пешкәк).

**ПЛУ'НЖЕРНЫЙ** *тех.* — плунжер...-ы, пешкәкле, плунжерлы; *плунжерный насос* — пешкәкле насос.

**ПЛУТ** *м.* — 1. хәйләкәр, хыянәтче, алдакчы, намуссыз кеше; 2. *разг. фам.* әрсез, шук, наян.

**ПЛУТА'ТЬ** *несов. разг.* — адашып йөрү.

**ПЛУТИ'ШКА** *м. разг. фам.* — алдакчы, хәйләкәр.

**ПЛУ'ТНИ** *разг.* — хәйләле эшләр, хыянәтле эшләр.

**ПЛУТОВА'ТОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.* — шуклык, хәйләкәрлек, алдашучанлык, хәрәмләшү.

**ПЛУТОВА'ТЫЙ** — 1. шуграк, хәйләкәррәк; *плутоватый ребёнок* — хәйләкәррәк (шуграк) бала; 2. хәйләле, шаян; *плутоватый взгляд* — хәйләле караш.

**ПЛУТОВА'ТЬ** *несов. разг.* — хәйләләү, алдашу, алдау, хәрәмләшү; *плутовать при игре в карты* — карта уенында хәрәмләшү.

**ПЛУТО'ВКА** *ж. разг.* — 1. хәйләкәр, алдакчы, хыянәтче (хатын-кыз); 2. әрсез, шук, наян (хатын-кыз).

**ПЛУТОВСКО'Й** — хәйләкәр, хәйләле, алдаулы, хәрәмләшүле, мәкерле; *плутовские приёмы игры в карты* — карта уенындагы хәрәмләшүле алымнар; *плутовская улыбка* — мәкерле (хәйләле) елмаю.

**ПЛУТОВСТВО'** *ср. мн.* нет — хәйләкәрлек, алдашу, хәрәмләшү; *грязное плутовство* — пычрак хәйләкәрлек.

**ПЛУТОКРА'Т** *м. книж. публиц.* — плутократ, байлыгы аркасында власте һәм йогынтысы булган кеше.

**ПЛУТОКРАТИ'ЧЕСКИЙ** *книж. публиц.* — плутократия...-ы, плутократик; *плутократический образ правления* — идарәнең плутократик формасы.

**ПЛУТОКРА'ТИЯ** *ж. мн.* нет, *книж. публиц.* — 1. плутократия, плутократлар идарәсе; 2. плутократлар.

**ПЛУТО'НГ** *м. воен. истор.* — плутонг, кечкенә җәяүле гаскәр отряды.

**ПЛЫВУ'Н** *м. спец.* — туфрак астындагы юеш юшкынлы катлау.

**ПЛЫВУ'ЧИЙ** *спец.* — сыек, сыекланган; су белән юылган; *плывучая глина* — сыекланган балчык.

**ПЛЫТЬ** *несов.* — 1. йөзү, йөзеп килү, йөзеп бару; 2. (пароходта, көймәдә) бару; *я плыл из Гамбурга в Лондон на небольшом пароходе (Тургенев)* — мин Гамбургтан Лондонга кечкенә генә пароходта бардым; *плыть на вёслах* — ишкәкләр белән ишеп бару; *плыть под парусами* — җилкән корып бару; 3. *разг.* ташу; *молоко плывёт* — сөт ташый. ◇ **Орёл плывёт под облаками** — бөркет болытлар янында йөзеп барган кебек оча. **Плыть по течению** *перен.* — ваемсыз яшәү, гамьсез яшәү. **Плыть в руки** *разг. шутл. ирон.* — үзе үк кулга килеп керү; җиңел юл белән табылу.

**ПЛЮВИО'ГРАФ** *м. физ. метеор.* — плювиограф (яуган яңгырның микъдарын язып бара торган прибор).

**ПЛЮВИО'МЕТР** *м. физ. метеор.* — плювиометр (яуган яңгырның микъдарын үлчәү приборы).

**ПЛЮГА'ВЕНЬКИЙ** *разг. фам.* — мескен генә кыяфәтле, килбәтсез генә, шыксыз гына, ягымсыз гына.

**ПЛЮГА'ВЕЦ** *м. простореч. бран.*— 1. шыксыз, килбәтсез, мескен; 2. кабахәт кеше, әшәке кеше.

**ПЛЮГА'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — килбәтсезлек, мескенлек, шыксызлык, ягымсызлык.

**ПЛЮГА'ВЫЙ** *разг. пренебр.*— мескен кыяфәтле, шыксыз, ягымсыз, килбәтсез; *плюгавый старикашка* — мескен кыяфәтле карт; *плюгавая собачонка* — шыксыз эт.

**ПЛЮМА'Ж** *м.*— каурый бизәк (баш киемен һәм ат сбруен бизәү өчен кулланыла); *шляпа с плюмажем* — каурый бизәкле эшләпә.

**ПЛЮ'НУТЬ** *сов.*— төкерү. ◇ **Раз плюнуть** *кому (простореч.)* — берни тормый (берәр нәрсәне эшләргә). **Плюнуть некуда** *разг. шутл. фам.*— 1. энә төртерлек урын юк (тыгызлык турында); 2. бик чиста (мәсәлән, бик чиста итеп җыештырылган өй турында әйтелә).

**ПЛЮР** *м. тип.*— плюр (үтә күренә торган юка кәгазь).

**ПЛЮРАЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *филос.*— плюрализм (идеалистик философик система — галәм һәм аның барлык күренешләре нигезендә берничә башлангыч ята дигән идеалистик караш).

**ПЛЮРАЛИ'СТ** *м. филос.* — плюралист (плюрализм тарафдары, плюрализмны яклаучы).

**ПЛЮРАЛИСТИ'ЧЕСКИЙ** *филос.* — плюрализм...-ы; плюралистик; *плюралистическая теория* — плюрализм теориясе.

**ПЛЮРА'ЛЬНЫЙ** *право.*— күп, берничә; плюраль. ◇**Плюральный вотум** — плюраль вотум (кайбер буржуаз илләрдә сайлаучыларның аерым категорияләренә өстәмә тавыш хокукы бирү).

**ПЛЮС** *м.* I — 1. плюс (а. кушу билгесе; б. уңай зурлык; в. җылылыкның, температураның нульдән югары икәнен күрсәтә торган билге); 2. *разг.* плюс, яхшы як, уңай як, өстенлек; *в этом есть свои плюсы* — моның үзенең яхшы яклары бар, моның үз плюслары бар; 3. өстәвенә, шуның өстенә; *он умён, плюс к этому красив* — ул акыллы, өстәвенә матур да.

**ПЛЮС** II *м. мн.* нет, *спец.*— комач, бурлат (материя).

**ПЛЮ'СКА** *ж. бот.*— кәшәнкә, кишәнкә, чәчәк төплеге, орлык табакчыгы.

**ПЛЮСНА'** *ж. анат.*— табан, аякның үкчәдән бармакларгача өлеше.

**ПЛЮСНЕВО'Й** *анат.*— табан...-ы; *плюсневые кости* — табан сөякләре.

**ПЛЮСОВА'ТЬ** *несов. тех.*— плюсовать итү (буяуга ману яки бизәк төшерү алдыннан тукымага махсус химик эретмә сеңдерү).

**ПЛЮСОВА'ТЬСЯ** *несов. тех.* — плюсовать ителү.

**ПЛЮСО'ВКА** *ж. тех.*— 1. к. плюсовать; 2. к. солильная машина.

**ПЛЮХ**— 1. *междом.* шап (берәр әйбернең килеп төшүен белдергән ымлык); 2. *разг. фам.* шап итеп килеп төшү, шап итеп утыру; *он со всего размаху плюх в кресло!* — ул креслога шап итеп килеп утырды.

**ПЛЮ'ХА** *ж. простореч.*— яңакка сугу, кундыру, яңакка чалтырату (уч белән); *закатить плюху кому-нибудь* — кемнең дә булса яңагына кундыру.

**ПЛЮ'ХАТЬ** *несов. разг. фам.*— к. плюхнуть.

**ПЛЮ'ХАТЬСЯ** *несов. разг. фам.* — к. плюхнуться.

**ПЛЮ'ХНУТЬ** *сов. разг. фам.*— к. плюхнуться.

**ПЛЮ'ХНУТЬСЯ** *сов. разг. фам.*— 1. шап итеп утыру; *плюхнуться на диван* — шап итеп диванга утыру; 2. шап итеп егылу; *плюхнуться в грязь* — шап итеп пычракка егылу.

**ПЛЮШ** *м. мн.* нет — плюш (бәрхетнекеннән озынрак йомшак йончалы тукыма).

**ПЛЮ'ШЕВЫЙ** — 1. плюш...-ы; *плюшевое производство* — плюш производствосы; 2. плюш(тан ясалган); *плюшевая обивка* — плюш тышлык.

**ПЛЮ'ШКИН** *м. книж. презрит.*— Плюшкин (чамадан тыш саран кеше. Гогольнең „Үле җаннар" исемле әсәрендәге помещик Плюшкин образы исеменнән алынган).

**ПЛЮ'ШКИНСТВО** *ср. мн.* нет, *книж. презрит.*— артык зур саранлык, чамасыз саранлык.

**ПЛЮЩ** *м. мн.* нет, *бот.*— чормавык, үрмәле гөл; *плющ вился вокруг дуба* — чормавык имәнгә чорналып үсә иде; *стена заросла плющем* — стенаны үрмәле гөлләр баскан.

**ПЛЮЩИ'ЛЬНИК** *м. спец.* — металлны яньчеп юкартучы.

**ПЛЮЩИ'ЛЬНЫЙ** *тех.*— яньчеп юкарту...-ы; *плющильный станок* — яньчеп юкарту станогы.

**ПЛЮ'ЩИТЬ** *несов.* — яньчеп юкарту.

**ПЛЯЖ** *м.* — пляж (елга яки диңгез буенда су коену өчен уңайлы комлык).

**ПЛЯС** *м. мн.* нет, *разг.*— бию; *пускаться в пляс* — биергә тотыну.

**ПЛЯСА'ТЬ** *несов. разг.* — бию (халык биюләрен). ◇ **Плясать под дудку** *чью* — к. дудка.

**ПЛЯ'СКА** *ж. разг.*— бию. ◇ **Пляска святого Витта** или **Виттова пляска** — аяк, кул яки баш калтырау авыруы.

**ПЛЯСОВО'Й** — бию...-ы; *плясовой мотив* — бию көе.

**ПЛЯСУ'Н** *м.*, **ПЛЯСУ'НЬЯ** *ж. разг.*— биюче, оста биюче.

**ПНЕВМА'ТИК** *м. тех.*— к. пневматика 2.

**ПНЕВМА'ТИКА** *ж.*—пневматика (1. *только ед. физ.* физиканың газсыман җисемнәрне өйрәнү бүлеге; 2. велосипедның яки автомобильнең шины).

**ПНЕВМАТИ'ЧЕСКИЙ** — 1. пневматик, тыгызланган һава тутырылган; *пневматическая камера* — пневматик камера; 2. пневматик, тыгызланган һава белән эшли торган; *пневматический насос* — пневматик насос.

**ПНЕВМОКО'КК** и **ПНЕ'ЙМОКОКК** *м.*—

пневмококк (пневмония авыруын тудыручы микроб).

**ПНЕВМОНИ'Я, ПНЕЙМОНИ'Я** *ж. мн. нет, мед.*— пневмония (үпкә ялкынсынуы).

**ПНИ'СТЫЙ** — агач төпләре күп булган; *пнистый лес* — агач төпләре күп булган урман.

**ПНИ'ЩЕ** *м. разг.*— зур агач төбе.

**ПНУТЬ** *сов. просторец.*— тибеп җибәрү.

**ПО** I *предлог с дат. п.* — 1. буйлап, буенча, ...-дан; *идти по дороге* — юл буйлап бару, юлдан бару; 2. ...-га; *разместить приезжих по комнатам* — килгән кешеләрне бүлмәләргә урнаштыру; 3. ...-дан; *узнать по голосу* — тавышыннан тану; 4. сәбәпле; *по болезни* — авыру сәбәпле; 5. буенча; *по договору* — договор буенча; 6. ...-ына, ...-енә карап; *по одежде встречают, по уму провожают* — киемενә карап каршы алалар, акылына карап озаталар; 7. ...-ларын; *по вечерам* — кичләрен; 8. *(со всеми числительными, кроме 2, 3, 4, 200, 300, 400)...* әр, ...-шәр, -...әрләп, ...-шәрләп, ...-дан; *по пяти* — бишәр, бишәрләп, бишәрдән; 9. ...-лап; *платить по часам* — сәгатьләп түләү. ◇ **Бриллиант по ореху** — чикләвек зурлыгындагы бриллиант. **Звать по имени** — исеме белән әйтү. **По праздникам** — бәйрәм көннәрдә. **По пятницам** — җомга көннәрдә. **Говорить по телефону** — телефоннан сөйләшү. **Тосковать по...** — ...-ны сагыну. **По происхождению** — чыгышы ягыннан. **Цыплят по осени считают** — чебешләрне көз җиткәч саныйлар. **По мне** — 1. минемчә; 2. яратам, миңа ошый. **Работать по профсоюзной линии** — профсоюз өлкәсендә эшләү. **По-моему** — минемчә. **По-твоему** — синеңчә. **По-нашему** — безнеңчә. **По-вашему** — сезнеңчә. **По-русски** — русча.

**ПО** II *предлог с вин. п.*— 1. ...-га чаклы, ...-дан, ...-гача; *войти в воду по пояс* — билгә чаклы суга керү, билдән суга керү; *по сегодня* — бүгенгә чаклы; 2. *(с числительными 2, 3, 4, 200, 300, 400)* ...-әр, ...-шәр, ...-әрләп, ...-шәрләп, ...-дан; *по два* — икешәр, икешәрләп, икешәрдән.

**ПО** III *предлог с предл. п.* —...-гач, ...-ганнан соң, ...-у белән; *по истечении срока* — срогы үткәч, срогы үтү белән.

**ПОАЛЕ'ТЬ** *сов. книж.*— алланып китү, аллану; *небо поалело перед восходом солнца* — кояш чыгар алдыннан күк йөзе алланып китте, кояш чыгар алдыннан күк йөзе алланды.

**ПОА'ХАТЬ** *сов. разг.* — ахылдашу, ахылдап алу, ахылдашып алу, ах итеп алу; *пришли, поахали, да с тем и ушли* — килделәр, ахылдаштылар да китеп тә бардылар.

**ПОБАГРОВЕ'ТЬ** *сов.*— куе кызыл төскә керү, бик нык кызарып китү, артык кызарып китү, кызарып китү; *небо побагровело от зарева* — күк йөзе кояш баеганда (яки: янгын шәүләсеннән) куе кызыл төскә керде; *побагроветь от гнева* — ачудан кызарып китү.

**ПОБА'ИВАТЬСЯ** *несов. ' разг.* — курку, куркыбрак тору; *все побаивались его язвительного языка* — барысы да аның ачы теленнән бераз куркалар иде.

**ПОБАЛАГУ'РИТЬ** *сов. разг.*— мәзәк сөйләп алу, сафсата сатып алу; мәзәк сөйләп тору, такмаза сатып тору.

**ПОБАЛА'КАТЬ** *сов. обл.*— бераз такылдап алу, такылдап тору, сөйләшеп тору.

**ПОБА'ЛИВАТЬ** *несов. разг.*— авыргалап алу; авыртыбрак тору; авырткалап китү, авыртып киткәләү; *у меня что-то и мозоль начинает побаливать — быть дождю (Гончаров)* — минем нишләптер сөялем дә авыртыбрак тора — яңгыр булыр ахры.

**ПОБАЛОВА'ТЬ** I *сов. разг.*— шаяртып алу, бераз назлап алу; *иногда ребёнка можно и побаловать* — кайвакыт баланы азрак назлап алырга да ярый. ◇ **Побалуйте меня табачком** — тәмәке белән сыйлагыз әле мине.

**ПОБАЛОВА'ТЬ** II *сов. разг.*— к. побаловаться.

**ПОБАЛОВА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— бераз шаярып алу, уйнап алу; *побаловался и будет* — бераз уйнап алдың, җитәр.

**ПОБАЛО'ВЫВАТЬ** *несов. разг. фам.*— к. побаловать.

**ПОБА'ЛТЫВАТЬ** I *несов. разг.*— селкеткәләп алу, селкетеп тору; вакыт-вакыт селкеткәләү; болгаткалап алу, болгатып тору, вакыт-вакыт болгаткалау.

**ПОБА'ЛТЫВАТЬ** II *несов. разг. фам.*— такылдап тору, бераз такылдау, бераз такылдап алу, бераз сөйләшеп алу.

**ПОБАСЁНКА**, *реже* **ПОБА'СЕНКА** *ж. разг.*— 1. *(забавный рассказец)* кечкенә көлке хикәя, такмаза; 2. буш әсәр, әһәмиятсез әсәр, әһәмияткә лаексыз әсәр.

**ПОБА'СКА** *ж. обл.*— к. побасенка.

**ПОБЕ'Г** *м.*— 1. качу, качып китү; 2. *бот. (новый росток)* яшь ботак, яшь сабак.

**ПОБЕ'ГАТЬ** *сов.*— бераз йөгереп алу, азрак йөгереп алу, йөгергәләү, бераз йөгерү.

**ПОБЕГУ'ШКИ: на побегушках** или **на побегушки** *разг.*— 1. вак-төяк йомышка йөрү; 2. *перен.* тулысынча буйсын(дырыл)ган (булу).

**ПОБЕ'ДА** *ж.*— җиңү, җиңеш, өстенлек казану.

**ПОБЕДИ'ТЕЛЬ** *м.*, **ПОБЕДИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж.*— җиңүче, җиңеп чыгучы, өстен чыгучы.

**ПОБЕДИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж. устар.*— к. победный I.

**ПОБЕДИ'ТЬ** *сов.*— җиңү, өстен чыгу, җиңеп чыгу; беренче булып чыгу (ярышта), алга чыгу, батыр калу.

**ПОБЕ'ДНЫЙ** I *книж.*— җиңү...-ы; *победная песнь* — җиңү җыры.

**ПОБЕ'ДНЫЙ** II *нар.-поэт.* — бәхетсез, көенечле, күп бәлагә очраган, кайгы-хәсрәтле; *победные головушки уснувших мужиков (Некрасов)*— йокыга талган мужикларның кайгы-хәсрәтле башлары.

**ПОБЕДОНО'СНЫЙ** *книж. торж.* — 1. җиңүле, җиңелмәс; *победоносная Советская Армия* — җиңелмәс Совет Армиясе.

◇ **Он говорил с победоносным видом** — ул җиңеп чыккан кыяфәт белән сөйли иде.

**ПОБЕЖА'ЛОСТЬ** *ж. мн.* нет, *хим. тех.* — (кыздырганда) төс үзгәртүчәнлек; *побежалость стали* — корычның төс үзгәртүчәнлеге.

**ПОБЕЖА'ЛЫЙ** *хим. тех.* — (металлны) кыздырганда барлыкка килә торган; *побежалые цвета* — (металлны) кыздырганда барлыкка килә торган төсләр.

**ПОБЕЖА'ТЬ** *сов.* — 1. йөгереп китү, йөгерә башлау; 2. качып китү; *противник побежал* — дошман качып китте; 3. *перен. разг.* ташый башлау; *молоко побежало* — сөт ташый башлады.

**ПОБЕЖДА'ТЬ** *несов.* — к. победить.

**ПОБЕ'ЖКА** *ж. спец.* — йөгереш, аллюр, чабу (ат).

**ПОБЕЛЕ'ТЬ** *сов.* — агару, агарыну, агарып китү.

**ПОБЕЛИ'ТЬ** *сов.* — агарту, агартып алу, акшарлау; *побелить потолок* — түшәмне агарту.

**ПОБЕ'ЛКА** *ж. мн.* нет — к. побелить.

**ПОБЕРЕ'ЖНЫЙ** — яр буендагы, яр буе ...-ы (су, елга кырыендагы, күл кырыендагы, диңгез кырыендагы).

**ПОБЕРЕ'ЖЬЕ** — яр буйлары (ярга якын җирләр, су буйлары, суга якын җирләр; яр буендагы, елга, күл, диңгез, океан буйларындагы җирләр); *побережье Волги* — Идел яры буйлары; *побережье Финского залива* — Фин култыгы буйлары.

**ПОБЕРЕ'ЧЬ** *сов. разг.* — саклау, саклап тору.

**ПОБЕРЕ'ЧЬСЯ** *сов.* — саклану, сакланып тору.

**ПОБЕСЕ'ДОВАТЬ** *сов.* — әңгәмә кору, әңгәмә сугу, сөйләшеп алу, бераз гәпләшеп алу.

**ПОБЕСИ'ТЬ** *сов. разг.* — җенләндерү, ярсыту, ачуын китерү, шаштыру, чыгырыннан чыгару, җен ачуын чыгару, җен ачуын китерү.

**ПОБЕСИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. җенләнү, шашынып алу, котырынып алу, артык кызу, шашыну, артык ачуланып алу; *побесился и успокоился* — шашынып алды да тынычланды; 2. уйнап алу, шаярып алу; *дети побесились* — балалар шаярып алдылар.

**ПОБЕСПОКО'ИТЬ** *сов.* — бераз борчып алу, тынычсызлау, тынычсызлап алу, бераз борчу, мәшәкатьләү.

**ПОБЕСПОКО'ИТЬСЯ** *сов.* — бераз борчылып алу, тынычсызланып алу, мәшәкатьләнү.

**ПОБЕ'ЧЬ** *сов. простореч. обл.* — к. побежать.

**ПОБИВА'ТЬ** *несов.* — 1. *воен.* җиңү, кыйнау (дошманны юк итү, кырып бетерү); 2. ватып бетерү, сындырып бетерү (күпне, барысын да).

**ПОБИВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. *воен.* җиңелү, кыйналу (дошман); 2. ватып бетерелү, сындырып бетерелү (күбе, барысы да).

**ПОБИРА'ТЬСЯ** *несов. разг.* — сорану, соранып йөрү, теләнеп йөрү, хәер соранып йөрү.

**ПОБИРА'ХА** и **ПОБИРА'ШКА** *м.* и *ж. обл.* — к. побируха, побирушка.

**ПОБИРУ'ХА** и чаще **ПОБИРУ'ШКА** *м.* и *ж. простореч.* — теләнче, хәерче, сораначы.

**ПОБИ'ТЬ** *сов.* — 1. кыйнап ташлау; *в драке его сильно побили* — сугышканда аны бик каты кыйнап ташлаганнар; 2. җиңеп чыгу, өстен чыгу; беренче урынга чыгу, алдан килү; *эта лошадь всех побила на скачках* — бу ат узышта иң алдан килде; 3. үтереп бетерү, кырып бетерү; *побить саранчу* — саранчаны үтереп бетерү; 4. ватып бетерү, кырып бетерү, челпәрәмә китереп бетерү; *побить посуду* — савыт-сабаны ватып бетерү; *градом побило все стёкла в окнах* — бозлы яңгыр барлык тәрәзә пыялаларын ватып бетерде; 5. сугу; *морозом побило рожь* — арышны суык сукты. ◇ **Побить градом** — боз сугу. **Побей или убей меня бог** *простореч.* — валлаһи, җир йотсын.

**ПОБИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. ватылып бетү, сытылып бетү, яньчелеп бетү; *яйца побились в дороге* — йомыркалар юлда ватылып беткән; 2. *разг.* тырышу, көч кую; *немало мы побились, прежде чем догадаться* — серенә төшенү өчен без аз көч куймадык. ◇ **Побиться об заклад** — к. биться.

**ПОБЛАГОДАРИ'ТЬ** *сов.* — рәхмәт әйтү, рәхмәт белдерү; *поблагодарить за гостеприимство* — кунакчыллык өчен рәхмәт белдерү.

**ПОБЛАЖЕ'НСТВОВАТЬ** *сов. разг. шутл.* — рәхәтләнеп алу, ләззәтләнеп алу, рәхәтләнеп калу.

**ПОБЛАЖИ'ТЬ** *сов. разг.* — юләрләнү, тилерү, юләрләнеп алу; *поблажил, хватит, пора и за ум взяться* — җитәрлек тилердең, акылга утырырга да вакыт.

**ПОБЛА'ЖКА** *ж. разг.* — яклау, иркәләү, узындыру; *вы им поблажку даёте* — сез аларны яклыйсыз, сез аларны узындырасыз.

**ПОБЛЕДНЕ'ТЬ** *сов.* — агарыну, агарынып китү, чырае китү, чырае бетү, чырае качу.

**ПОБЛЁКЛЫЙ** — сулган, шиңгән, пәжегән; *поблёклый цветок* — шиңгән чәчәк, сулган чәчәк.

**ПОБЛЁКНУТЬ** *сов.* — сулу, шиңү, пәжү.

**ПОБЛЁСКИВАТЬ** *несов.* — ялтырап-ялтырап кую, ялтырап китү, чагылып китү, ялтыр-йолтыр итү, ялтыр-йолтыр килү; *поблёскивали штыки в темноте* — караңгыда штыклар ялтыр-йолтыр киләләр иде.

**ПОБЛЕСТЕ'ТЬ** *сов. книжн.* — (бераз вакыт) ялтырап тору; *звёзды поблестели в небе и погасли перед зарёй* — күктә йолдызлар ялтырап тордылар да таң алдыннан сүнделәр.

**ПОБЛИ'ЗОСТИ** *нареч.* — якын тирәдә, якын гына, якында гына; *дача расположена поблизости от города* — дача шәһәргә якын гына урнашкан.

**ПОБЛИСТА'ТЬ** *сов. книжн.* — 1. бераз ялтырап тору; 2. *перен.* данлыклы булып тору, өстен булып тору (берникадәр вакыт).

**ПОБОЖИ'ТЬСЯ** *сов.* — к. божиться.

**ПОБО'И** *вд.* нет — кыйнау, сугу; *следы побоев* — суккан эзләр.

**ПОБО'ИЩЕ** *ср.* — 1. зур сугыш; 2. сугыш урыны; 3. *разг. неодобр.* или *ирон.* канлы кыйнаш; 4. *перен. разг. шутл.* зур талаш, зур ызгыш.

**ПОБОЛЕ'ТЬ** *сов.* — авыртып алу, авырып алу; *голова поболела с утра, а к вечеру прошла* — иртән баш авыртып алды да, кич белән бетте.

**ПОБОЛТА'ТЬ I** *сов.* — 1. *разг.* болгатып алу, болгату; *поболтать раствор* — эретмәне болгатып алу; 2. селкетү, селкетеп алу; *поболтал ногами под одеялом и закутался (Л. Толстой)* — юрган астында аякларын селкетеп алды да башыннан ук ябынды.

**ПОБОЛТА'ТЬ II** *сов. разг.* — бераз лыгырдау, лыгырдап алу, бераз такылдау, такылдап алу, ләчтит сатып алу; *поболтать о пустяках* — юк-бар нәрсәләр турында такылдап алу.

**ПОБО'Р** *м. неодобр.* — 1. *только мн.* к. поборы; 2. взятка, ришвәт.

**ПОБО'РНИК** *м.*, **ПОБО'РНИЦА** *ж. книж. ритор.* — бик тырышып яклаучы, чын күңелдән, ихлас күңелдән яклаучы, чын күңелдән, ихлас күңелдән көрәшүче, бирелеп көрәшүче; *поборник правды и справедливости* — дөреслекне һәм гаделлекне чын күңелдән яклаучы, дөреслек һәм гаделлек өчен көрәшүче.

**ПОБОРО'ТЬ** *сов.* — 1. җиңү, егу, җиңеп чыгу; *борец поборол своего противника* — көрәшче үзе белән көрәшүчене җиңеп чыкты; *он поборол всех конкурентов* — ул барлык конкурентларын җиңде; 2. *перен.* җиңү, басу, бетерү; *побороть в себе чувство страха* — үзеңнең куркуыңны басу.

**ПОБОРО'ТЬСЯ** *сов.* — көрәшү, көрәшеп алу; *давай, поборемся для тренировки* — әйдә, тренировка өчен көрәшеп алыйк; *мы ещё поборемся* — без әле көрәшербез.

**ПОБО'РЫ** *неодобр. устар.* — зур салым, күтәрә алмаслык салым.

**ПОБО'ЧНЫЙ** — 1. төп булмаган, өстәмә, икенче дәрәҗәдәге; *побочные соображения* — өстәмә фикерләр; *он играл в этом деле побочную роль* — ул бу эштә икенче дәрәҗәдәге рольне уйнады; *побочный продукт производства* — производствоның өстәмә продукты; 2. *дореvол.* никахсыз табылган; *побочный сын* — никахсыз туган ул (малай).

**ПОБОЯ'ТЬСЯ** *сов.* — курку; *я не побоюсь сказать ему всю правду* — мин аңа барлык дөреслекне әйтүдән курыкмам; *хотел пойти, да побоялся* — бармакчы идем дә, курыктым.

**ПОБРА'НИВАТЬ** *несов. разг.* — вакыт-вакыт шелтәләп алу, орышып алу, тиргәп алу, тиргәштергәләү.

**ПОБРА'НИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — тиргәшеп алу, тиргәшү, орышышып алу, орышышу (вакыт-вакыт); *старики лениво побраниваются* — картлар иренеп кенә тиргәшеп алалар иде.

**ПОБРАНИ'ТЬ** *сов.* — орышу, орышып алу, тиргәү, шелтәләү, шелтәләп алу.

**ПОБРАНИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — орышышып алу, талашып алу, тиргәшеп алу, тиргәшү; *покупатель побранился с продавцом* — сатып алучы сатучы белән орышышып алды.

**ПОБРА'СЫВАТЬ** *несов.* — ыргыткалау, ташлаштыргалау (вакыт-вакыт); *сидел на крыльце и побрасывал хлеб собакам* — баскычта утырып, этләргә икмәк ыргыткалый иде.

**ПОБРАТА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. дуслашу, туганлашу; 2. *обл.* и *истор.* бер-береңә дуслыкны бозмау турында ант итү, дуслыкны өзмәскә сүз бирешү.

**ПОБРАТИ'М** *м.* — 1. туганлашкан дус; 2. *обл.* этисенең яки әнисенең туганыннан туган абый (яки эне).

**ПОБРАТИ'МСТВО** *ср. мн.* нет, *истор.* — туганлашу, ахирәт дус булу (коньяк славяннарда дуслыкны аерым йолалар белән туганлык дәрәҗәсенә җиткерү гадәте).

**ПОБРА'ТЬ** *сов. простореч.* — алып бетерү; алу; *побрали всех в солдаты* — барысын да солдатка алып бетерделәр. ◇ **Чорт бы тебя побрал** или **чорт тебя побери** *разг. бран.* — шайтан алгыры.

**ПОБРЕ'ЗГАТЬ** *сов. разг.* — җирәнү; *знатная барыня этим не побрезгала (Тургенев)* — дәрәҗәле ханым моннан җирәнмәде. ◇ **Не побрезгайте** *простореч.* — рәхим итегез, ашап карагыз.

**ПОБРЕ'ЗГОВАТЬ** *сов. простореч.* — к. побрезгать.

**ПОБРЕСТИ'** *сов.* — салмак атлап китеп бару, әкрен генә китеп бару.

**ПОБРИ'ТЬ** *сов.* — кырып алу, кыру (сакал-мыекны, чәчне).

**ПОБРИ'ТЬСЯ** *сов.* — кырынып алу, кырыну.

**ПОБРОДИ'ТЬ I** *сов.* — 1. *разг.* бераз йөрү, бераз йөреп алу; *побродить по лесу* — бераз урманда йөреп алу; бераз урманда йөрү; 2. *разг.* (*много поездить*) күп йөрү, күпне күреп йөрү; 3. *спец.* (*половить рыбу бреднем*) бераз балык сөзү.

**ПОБРОДИ'ТЬ II** *сов.* — әчү, әчеп тору; *квас достаточно побродил* — квас җитәрлек әчегән.

**ПОБРОДЯ'ГА** *м. простореч. устар. бран.* — к. бродяга.

**ПОБРОСА'ТЬ** *сов.* — 1. (төрле җиргә) ташлап калдыру; *воры побросали похищенное* — караклар урлаган әйберләрен төрле җиргә ташлап калдырганнар; 2. ташлап калдыру, калдыру; *нянька побросала детей и ушла* — бала караучы балаларны калдырып киткән; 3. ыргытып тору, бераз (вакыт) ыргыткалау.

**ПОБРЫ'ЗГАТЬ** *сов.* — 1. бөркеп алу; сибәләп алу, бераз явып алу; чәчрәтеп алу; *побрызгать растения из пульверизатора* — үсемлекләргә пульверизатордан су бөркеп алу; *дождик побрызгал и перестал* — янгыр сибәләп алды да туктады.

**ПОБРЫ'ЗГАТЬСЯ** *сов.* — чәчрәтешү, чәчрәтешеп алу; *дети вдоволь побрызгались в ванне* — балалар ваннада туйганчы чәчрәтештеләр.

**ПОБРЮЗЖА'ТЬ** *сов. разг.* — мыгырданып кую.

**ПОБРЯ'КАТЬ** *сов. разг.* — шалтырату, шылтыратып алу, бераз шылтырату.

**ПОБРЯ'КИВАТЬ** *несов. разг.* — к. побрякать.

**ПОБРЯКУ'ШКА** *ж. разг. пренебр.* — шылтыравык (уенчык).

**ПОБУДИ'ТЕЛЬ** *м. книж.* — мәҗбүр итүче сәбәп, тудыручы сәбәп.

**ПОБУДИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — **1.** мәҗбүр итүче, мәҗбүр итә торган; **2.** тудыра торган, барлыкка китерүче, уята торган.

**ПОБУДИ'ТЬ** I *сов.* — **1.** уяту, уятырга тырышу; **2.** *охот. (поднять с лёжки)* торгызу (ерткыч хайванны).

**ПОБУДИ'ТЬ** II *сов. книж.* — мәҗбүр итү, кызыксындыру, теләк тудыру, сәбәп булу.

**ПОБУ'ДКА** *ж. спец. воен.* — уяту сигналы; *утренняя побудка в лагере* — лагерьда иртәнге уяту сигналы.

**ПОБУЖДА'ТЬ** *несов. книж.* — к. побудить II.

**ПОБУЖДА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — кызыксындырылу, теләк тудырылу, мәҗбүр ителү.

**ПОБУЖДЕ'НИЕ** *ср. книж.* — теләк, уй.

**ПОБУРЕ'ТЬ** *сов.* — көрәнләнү, көрән төскә керү.

**ПОБЫВА'ЛЬЩИНА** *ж. простореч.* и *лит.* — (булган эш, вакыйга турында) телдән сөйләнгән хикәя, сөйләк.

**ПОБЫВА'ТЬ** *сов.* — **1.** булу (төрле җирдә); *он побывал во Франции и в Испании* — ул Франциядә һәм Испаниядә булган; **2.** *разг.* керү, кереп чыгу; *надо побывать в конторе и успеть на поезд* — конторага кереп чыгарга да, поездга өлгерергә дә кирәк; *побывайте и у нас, когда вернётесь* — кайткач безгә дә кереп чыгыгыз, кайткач безгә дә рәхим итегез.

**ПОБЫ'ВКА** *ж. разг.*: солдат приехал на побывку — солдат кунакка кайтты.

**ПОБЫ'ТЬ** *сов.* — булу, бераз булу, бераз тору, булып алу; *не уходи, побудь со мной* — китмә, бераз минем белән бул; *он у нас побыл два дня и уехал* — ул бездә ике көн булды да китте.

**ПОВА'ДИТЬ** *сов. разг.* — ияләштерү, өйрәтү, гадәтләндерү; *повадил собаку ходить к нам на двор* — этне безнең йортка килергә ияләштерде.

**ПОВА'ДИТЬСЯ** *сов. разг.* — **1.** гадәтләнү, ияләшү, өйрәнү (начар гадәтләргә); *кошка повадилась в чулан лазить* — мәче чоланга керергә гадәтләнгән; **2.** бик еш килеп йөри башлау; *он повадился к нам каждый вечер* — ул безгә һәр кичне килә башлады.

**ПОВА'ДКА** *ж. разг. неодобр.* — **1.** гадәт; ияләнгән эш; *у собаки повадка хватать за ногу* — этнең гадәте — аяктан кабу (эләктерү); **2.** үз-үзен тотуы, манерасы, гадәтләре; *оставь эту повадку* — бу гадәтеңне ташла.

**ПОВА'ДЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.* — бик җиңел бирелүчәнлек, тиз килешүчәнлек, аумакайлык, ярарга тырышучанлык, ялагайлык; *советники, добывшие свои чины повадливостью (Салтыков-Щедрин)* — үзләренең чиннарын ялагайлык белән казанган советниклар.

**ПОВА'ДЛИВЫЙ** *разг.* — **1.** тиз килешүчән, бик җиңел бирелүчән, ялагай, аумакай, ярарга тырышучан; **2.** *обл.* йөдәтүчән, йөдәткеч; *повадливый гость* — йөдәткеч кунак.

**ПОВА'ДНО** *безл. разг.*: чтобы не было повадно —(икенче тапкыр эшләмәскә) сабак булсын өчен.

**ПОВА'ДЧИК** *м. разг. простореч.* — өйрәтүче, гадәтләндерүче, ияләштерүче, юл куючы (берәр эшкә).

**ПОВА'ЖИВАТЬ** I *несов. разг.* — к. повадить.

**ПОВА'ЖИВАТЬ** II *несов. разг.* — йөрткәләү, вакыт-вакыт йөртү; *поваживал ребят по кино да по театрам* — балаларны кино, театрларга йөрткәли иде.

**ПОВА'ЖИВАТЬ** III *несов. разг.* — ташыштыргалау, вакыт-вакыт ташу; *поваживал товары в город* — шәһәргә товар ташыштыргалый иде.

**ПОВА'ЖНИЧАТЬ** *сов. разг.* — **1.** кукраеп алу; *поважничал недавно он* — ул озак кукрая алмады; **2.** үзен-үзе зурга санау, эреләнеп тору; *он только поважничал, а в конце концов согласился с нами ехать* — ул бераз эреләнеп торды да соңыннан безнең белән барырга риза булды.

**ПОВА'КСИТЬ** *сов. разг.* — ваксалау, ваксалап алу, вакса белән ялтыратып алу, ялтырату (мәсәлән, итекләрне).

**ПОВА'ЛИВАТЬ** *несов. разг.* — к. повалять 1.

**ПОВАЛИ'ТЬ** I *сов.* — аудару, егу; *повалить соперника на землю* — үзең белән көрәшүчене егу; *ветер повалил забор* — җил койманы аударды, җил койманы аударган.

**ПОВАЛИ'ТЬ** II *сов. разг.* — **1.** агылу, ябырылу (халык); *народ повалил на площадь (Пушкин)* — халык мәйданга таба агылды; **2.** ургылып чыга башлау; *дым повалил из трубы* — трубадан төтен ургылып чыга башлады; **3.** ява башлау; *снег повалил хлопьями* — ябалак кар ява башлады.

**ПОВАЛИ'ТЬСЯ** *сов.* — **1.** аву; *забор повалился* — койма ауды; **2.** аву, яту (егылу); *повалиться на постель* — урынга аву (егылу).

**ПОВА'ЛЬНЫЙ** — гомуми, берсен дә калдырмыйча...; *повальный обыск* — гомуми тентү. ◇ Повальная болезнь *разг.* — үләт авыруы, кизү.

**ПОВАЛЯ'ТЬ** *сов.* — **1.** аунату; *повалять котлеты в сухарях* — котлетларны сохари онында аунату; **2.** егу, аудару (берничә тапкыр яки берникадәр); *все кегли повалял* — барлык кегльләрне аударды; **3.** *разг.* аунатып бетерү, әвәләп туктау.

**ПОВАЛЯ'ТЬСЯ** *сов.* — **1.** аунап алу; *собака повалялась по траве* — эт үләндә аунап алды; **2.** *разг.* (*полежать в постели*) бераз ятып тору.

**ПОВА'ПЛЕННЫЙ** *книж.*: гроб повапленный — икейөзле эшәке кеше.

**ПО'ВАР** *м.* — повар, аш пешерүче оста, пешекче.

**ПОВА'РЕННЫЙ** *страд.* — 1. пешкән, пешерелгән; 2. аш...-ы; *поваренная соль* — аш тозы; 3. аш пешерү...-ы; *поваренное искусство* — аш пешерү осталыгы. ◇ **Поваренная книга** — төрле ашлар пешерергә өйрәткән кулланма, пешекче китабы.

**ПОВАРЁНОК** *м. разг.* — повар ярдәмчесе (малай).

**ПОВАРЁШКА** *ж. спец обл.* — 1. аш чүмече; 2. сөзгеч.

**ПОВА'РИВАТЬ** *несов. разг.* — әкрен генә пешереп тору, әз-әзләп кенә пешерү; *стоит у плиты да поваривает суп* — плита янында басып, әкрен генә аш пешереп тора.

**ПОВА'РИТЬ** *несов. простореч. устар.* — к. поварничать.

**ПОВА'РИ'ТЬ** *сов.* — пешерә төшү, пешерү; *надо поварить картофель ещё несколько минут* — бәрәңгене тагы берничә минут пешерергә кирәк.

**ПОВАРИ'ТЬСЯ** *сов.* — пешү, пешә төшү; *пусть мясо ещё немного поварится* — ит тагы да бераз пешә төшсен әле.

**ПОВАРИ'ХА** *ж. спец.* — к. повар.

**ПОВА'РНИЧАТЬ** *несов. разг. устар.* — аш пешерү, аш пешерү белән шөгыльләнү, поварлык итү.

**ПОВА'РНЯ** *ж. разг. устар.* — кухня, аш пешерү бүлмәсе.

**ПОВАРСКА'Я** *ж. устар.* — зур кухня (ресторaннарда, байлар өйләрендә).

**ПОВАРСКО'Й** — повар...-ы; *поварской нож* — повар пычагы.

**ПОВЕВА'ТЬ** *несов. книж.* — 1. исеп алу, исеп-исеп алу, исеп-исеп кую, искәләү (жил); 2. жилләндереп алу (жилпәзә, жилләткеч белән).

**ПОВЕ'ДАТЬ** *сов. книж. устар.* и *ритор.* — сөйләп бирү, әйтеп бирү; *поведать свою тайну* — серне чишү, серне әйтеп бирү.

**ПОВЕДЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — үз-үзенне тоту, әхлак, тәртип, дисциплина; *отличное поведение* — бик яхшы тәртип (мәсәлән, мәктәп баласының).

**ПОВЕ'ДОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж. устар.* и *ритор.* — к. поведать.

**ПОВЕ'ДЫВАТЬ** *несов. книж. устар. ритор.* — к. поведать.

**ПОВЕЗТИ'** *сов.* — 1. алып бару, алып китү, илтү; *крестьяне повезли в город сено* — крестьяннар шәһәргә печән алып киттеләр; *я сам повезу его в больницу* — мин үзем аны больницага илтермен; 2. *разг.* алып бара алу, илтә алу; *эту кладь всякая лошадь повезёт* — бу йөкне теләсә нинди ат алып бара алыр; 3. *разг. безл.* уңу, уңышлы булып чыгу, барып чыгу; *ему повезло* — ул уңды, аның эше уңышлы булып чыкты.

**ПОВЕЛЕВА'ТЬ** *несов. книж. торж.* — 1. *устар.* идарә итү; *повелевать страной* — ил белән идарә итү; 2. кушу, боеру, боерык бирү; *повелевать подданным* — үзеңә буйсынганнарга боерык бирү; *так повелевает мне долг* — миңа намусым шулай куша.

**ПОВЕЛЕ'НИЕ** *ср. книж. устар. торж.* — боерык, фәрман; *получить повеление* — боерык алу, фәрман алу.

**ПОВЕЛЕ'ТЬ** *сов. книж. торж. устар. офиц.* — боеру, боерык бирү, фәрман бирү, кушу.

**ПОВЕЛИ'ТЕЛЬ** *м.*, **ПОВЕЛИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж. книж. торж. устар.* — падишаһ, хаким, патша.

**ПОВЕЛИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — катгыйлык, кискенлек, боеручанлык; *повелительность тона* — тавышның катгыйлыгы (кискенлеге).

**ПОВЕЛИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — 1. боеру ...-ы; *говорить повелительным тоном* — боеру тоны белән сөйләү; 2. катгый, кискен. ◇ **Повелительное наклонение** *грам.* — боерык фигыль.

**ПОВЕНЧА'ТЬ** *сов.* — никах укыту, никах уку, никахландыру.

**ПОВЕНЧА'ТЬСЯ** *сов.* — никахлану.

**ПОВЕРГА'ТЬ** *несов. книж.* — к. повергнуть.

**ПОВЕРГА'ТЬСЯ** *несов. книж.* — к. повергнуться.

**ПОВЕ'РГНУТЬ** *сов. книж.* — 1. *ритор.* аудару, егу; *буря повергла дуб* — давыл имәнне аударды; *болезнь повергла его в постель* — авыру аны аяктан екты; 2. төшерү, салу, калдыру (авыр хәлгә); *эта весть повергла меня в отчаяние* — бу хәбәр мине тирән кайгыга төшерде. ◇ **Повергнуть к стопам** *офиц. устар.* — аягына егылу, баш ору (берәр нәрсә үтенеп). **Повергнуть на благоусмотрение** *офиц. устар.* — карамагына бирү, тапшыру (зур кешенең, падишаһның).

**ПОВЕ'РГНУТЬСЯ** *сов. книж.* — 1. *ритор.* җимерелеп төшү, ишелеп төшү; *земля дрогнула, и скалы поверглись (Даль)* — җир тетрәп китте, һәм кыялар җимерелеп төште; 2. төшү, эләгү (авыр хәлгә); *повергнуться в отчаяние* — өметсезлеккә төшү.

**ПОВЕ'РЕННЫЙ** — 1. тикшерелгән, дөресләнгән; 2. ышанып тапшырылган; 3. ышанычлы, вәкил; *поверенный по торговым делам* — сәүдә эшләре буенча вәкил; 4. (*наперсник*) ышанычлы кеше, сердәш. ◇ **Присяжный поверенный** *офиц. дорев.* — адвокат.

**ПОВЕ'РИТЬ** *сов.* — 1. ышану; *поверить слуху* — сүзгә ышану; 2. к. поверять 1, 2; 3. ышанып тапшыру; *поверить деньги кому-н.* — берәр кешегә акчаны ышанып тапшыру.

**ПОВЕ'РКА** *ж.* — 1. тикшерү, дөресләү; *поверка времени* — сәгатьне дөресләү; *поверка знаний* — белемне тикшерү; 2. барлап чыгу, барлау; *вечерняя поверка в казарме* — казармада кичке барлау.

**ПОВЕРНУ'ТЬ** *сов.* — 1. бору; *повернуть кран* — кранны бору; *кучер повернул лошадей налево* — кучер атларны сулга борды; 2. борылу; *когда дойдёшь до угла, поверни направо* — чатка барып җиткәч, уңга борыл; 3. әйләндереп яткыру; *повернуть больного на другой бок* — авыруны

икенче ягына әйләндереп яткыру; 4. *перен. разг.* (икенчегә) бору, (үзенчә) борып җибәрү; *повернул дело по своему* — эшне үзенчә борып җибәрде; *повернуть разговор* — сүзне икенчегә бору. ◇ **Повернуть оглобли** — к. оглобли.

**ПОВЕРНУ'ТЬСЯ** *сов.*—1. борылу; *повернулся ко мне лицом* — йөзе белән миңа таба борылды; 2. әйләнү; *повернуться на другой бок* — икенче якка әйләнү; 2. *перен.* борылып китү, әйләнеп китү; *дело повернулось иначе* — эш башкачага әйләнеп китте. ◇ **Язык не повернулся или не повернётся** — тел бармады, тел әйләнмәде, яки тел бармас, тел әйләнмәс; *язык не повернулся рассказать ему всё* — барысын да сөйләп бирергә телем бармады.

**ПОВЕ'РОЧНЫЙ** *офиц.*— сынау...-ы; тикшерү...-ы; *поверочные испытания* — сынау имтиханнары.

**ПОВЕРСТА'ТЬ** *сов.*—1. *истор.* (*наделять поместьем, окладом* и т. д.) бүлеп бирү; бүләк итеп бирү, бирү; 2. *обл.* (*сравнить*) чагыштыру.

**ПОВЕРСТА'ТЬСЯ** *сов. обл.*— тигезләнү, янәшә басу.

**ПОВЁРСТНЫЙ** — чакрым башыннан..., чакрым исәбеннән...; чакрымлап..., чакрым саен...; *повёрстная плата* — чакрым башыннан түләү.

**ПОВЕРТЕ'ТЬ** *сов.*— әйләндереп җибәрү, әйләндереп тору; *повертеть колесо* — тәгәрмәчне әйләндереп тору.

**ПОВЕРТЕ'ТЬСЯ** *сов.*—1. бераз әйләнү, әйләнеп алу; *колесо повертелось и остановилось* — тәгәрмәч бераз әйләнде дә туктады; 2. *разг. пренебр.* әйләнгәләп алу, боргалану; әйләнгәләү; *он пришёл, повертелся и ушёл* — ул килеп, әйләнгәләде дә китеп тә барды; *повертеться перед зеркалом* — көзге каршында боргалану.

**ПОВЁРТКА** *ж.*, **ПОВЁРТОК** *м. обл.*— юл борылышы; *идти до повёртки* — юл борылышына кадәр бару.

**ПОВЁРТЫВАТЬ** *несов.*— к. повернуть.

**ПОВЁРТЫВАТЬСЯ** *несов.*—1. к. повернуться; 2. *страд.* әйләндерелү.

**ПОВЕ'РХ** *предлог с род. п.*— өстеннән; *надеть плащ поверх шубы* — тун өстеннән плащ кию.

**ПОВЕ'РХНОСТНО** *нареч.* — өстән генә, сай, өстән-өстән генә; *судить о чём-нибудь поверхностно* — берәр нәрсә турында өстән-өстән генә фикер йөртү.

**ПОВЕ'РХНОСТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— сайлык, өстән-өстән генә булучылык (белем, караш һ. б.); *поверхностность взглядов* — карашларның сайлыгы.

**ПОВЕ'РХНОСТНЫЙ** —1. *книж.* өске; *поверхностный слой почвы* — туфракның өске катлавы; 2. *спец.* җир өсте...-ы; җир өстендәге; *поверхностные работы* — җир өсте эшләре; 3. *физ.* өслек...-ы; *поверхностные волны* — өслек дулкыннары; 4. *перен.* сай, тирән булмаган, җитди булмаган, өстән...; җиңел...; *поверхностный взгляд* — җиңел караш; *поверхностное знания* — сай белем; *поверхностный человек* — сай кеше.

**ПОВЕ'РХНОСТЬ** *ж.*—1. өс(т); *поверхность земли* — җир өсте; *поверхность воды* — су өсте; 2. *мат.* өслек; *поверхность шара* — шарның өслеге; *поверхность круга* — түгәрәкнең өслеге. ◇ **Скользить по поверхности** *ирон. перен.*— өстән-өстән генә йөзү, сай йөзү. **Несущая поверхность** *ав.*— самолёт канатларының аскы ягы.

**ПО'ВЕРХУ** *нареч. разг.*—1. өстән, өске яктан; *крыша поверху крыта толем* — өй түбәсе өстән толь белән ябылган; 2. *перен.* өстән генә; *автор скользит поверху, не вдаваясь в анализ* — автор, анализга керешеп тормыйча, өстән генә йөзә.

**ПОВЕ'РЧИВАТЬ** *несов. разг.*— әйләндергәләп алу, әйләндергәләү.

**ПОВЕРШИ'ТЬ** *сов. обл.*—1. очлау; *повершить скирду* — эскертне очлау; 2. *перен. устар.* бетереп кую, бетерү, тәмамлап кую, тәмамлау (берәр нәрсәне, эшне).

**ПОВЕ'РЬЕ** *ср.*— ышану (халыкның гадәтйола буенча ышануы).

**ПОВЕРЯ'ЛЬЩИК** *м. спец.*— тикшерүче (эшче, специалист); *поверяльщик машин в прядильном производстве* — эрләү производствосында машиналарны тикшерүче.

**ПОВЕРЯ'ТЬ** *несов.*—1. (*производить проверку*) тикшерү, тикшереп чыгу; 2. ышанып сөйләү, ышану, сер сөйләү; 3. ышанып бирү, ышанып тапшыру.

**ПОВЕРЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— тикшерелү, тикшереп чыгылу.

**ПОВЕ'СА** *м. разг.*— шаян, шук; ялкау.

**ПОВЕСЕЛЕ'ЛЫЙ** *разг.*— кәефе килгән, кәефле.

**ПОВЕСЕЛЕ'ТЬ** *сов.*— күңел ачылып китү, кәеф килү, кәефләнебрәк китү, ачылып китү.

**ПОВЕСЕЛИ'ТЬ** *сов.*— (кемнең дә булса) күңелен ачу, кәефен күтәрү.

**ПОВЕСЕЛИ'ТЬСЯ** *сов.*— күңел ачып алу, кәефләнеп алу.

**ПОВЕ'СИТЬ** *сов.*—1. элеп кую, асып кую; 2. асып үтерү. ◇ **Повесить голову или нос** — борын салындыру.

**ПОВЕ'СИТЬСЯ** *сов.*— асылынып үлү.

**ПОВЕ'СНИЧАТЬ** *несов. разг.*— шаяру, шаянланып йөрү; трай тибү.

**ПОВЕСТВОВА'НИЕ** *ср. книж.*— (берәр нәрсә, вакыйга турында) сөйләп бирү, язып бирү.

**ПОВЕСТВОВА'ТЕЛЬ** *м. книж. устар.*— хикәяләүче, сөйләүче, сөйләп бирүче.

**ПОВЕСТВОВА'ТЕЛЬНЫЙ** *книж. лит.*— 1. повесть...-ы; озын хикәя...-ы; *повествовательный стиль* — повесть стиле (озын хикәя стиле); *повествовательный жанр* — озын хикәя жанры; 2. *перен.* тыныч, эпик; *повествовательный тон* — тыныч тон. ◇ **Повествовательное предложение** *грам.*— хикәя җөмлә.

**ПОВЕСТВОВА'ТЬ** *несов. книж.*— хикәяләп бирү, сөйләп бирү, язып бирү.

**ПОВЕСТИ'** *сов.*—1. алып китү, алып бару; *повести войска на приступ* — гаскәрләрне һөҗүмгә алып китү; 2. (салмак кына) йөртеп чыгу; *повёл смычком по струне* — смычокны скрипка кылы буйлап (салмак кына) йөртеп чыкты; 3. үзен тоту; *в этом деле он повёл себя недурно* — бу эштә ул үзен әйбәт кенә тотты; 4. *безл.* калҗаю; *повело доску от сырости* — такта юешлектән калҗайган; 5. сикертеп алу, җыерып алу; *повести бровями* — кашларны сикертеп алу; *повести плечом* — кулбаш сикертү.

**ПОВЕСТИ'СЬ** *сов. разг.*—1. бәйләнешкә керү, дуслашу; 2. килү, гадәткә керү, гадәтләнү; *исстари так повелось* — элек-электән шулай гадәткә кергән. ◇ **С кем поведёшься, от того и наберёшься** — кем чанасына утырсаң, шуның җырын җырларсың.

**ПОВЕСТИ'ТЬ** *сов. устар.* и *обл.*— хәбәр итү, белдерү.

**ПОВЕ'СТКА** *ж.*—1. повестка, белдермә, чакыру кәгазе, чакыру язуы; 2. кисәтү сигналы (мәсәлән, поезд китәр алдыннан бирелә торган сигнал). ◇ **Повестка дня** *офиц.*— көн тәртибе; *в повестке дня* или *на повестке дня* — көн тәртибендә, чиратта.

**ПОВЕСТУ'ШКА** *ж. разг. пренебр.*— кечкенә повесть, әһәмиятсез хикәя.

**ПО'ВЕСТЬ** *ж. лит.*—1. повесть, озын хикәя; 2. *устар.* хикәяләү, сөйләп бирү.

**ПОВЕ'Т** *м. истор.*— өяз (Украинада).

**ПОВЕ'ТОВЫЙ** *истор.*— өяз...-ы; *поветовый суд* — өяз суды.

**ПОВЕ'ТРИЕ** *ср. разг.*— кизү (тиз тарала торган йогышлы авыру).

**ПОВЕ'ТЬ** *ж. обл.*— лапас.

**ПОВЕЧЕРЕ'ТЬ** *сов.*— кич җитү.

**ПОВЕЧЕ'РЯТЬ** *сов. обл.*— кичке ашны ашап алу.

**ПОВЕ'ШЕНИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— асып үтерү, асу.

**ПОВЕ'ШАННЫЙ**—1. эленгән, асылган; 2. (*казнённый через повешение*) асып үтерелгән, асылган.

**ПОВЕЩА'ТЬ** *несов. устар.* и *обл.*— к. повестить.

**ПОВЕ'ЯТЬ** *сов.*—1. исеп китү, исә башлау; 2. *(немного провеять зерна)* җилгәреп алу (ашлыкны).

**ПОВЗВО'ДНО** *нареч. воен.*— взводлап; *строиться повзводно* — взводлап тезелү.

**ПОВЗДО'РИТЬ** *сов. разг.*— орышышу, тиргәшеп алу.

**ПОВЗРОСЛЕ'ТЬ** *сов.*— олыгаеп китү, олыгаю.

**ПОВИВА'ЛЬНЫЙ** *устар.*— акушерлык ...-ы, әбилек кылу...-ы; *повивальное искусство* — акушерлык осталыгы. ◇ **Повивальная бабка** *устар.*—кендек әбисе.

**ПОВИВА'ТЬ** *несов.*— к. повить I.

**ПОВИДА'ТЬ** *сов. разг.*— күрү, күрешү, очрашу; *повидать друзей* — дуслар белән күрешү.

**ПОВИДА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— очрашу, күрешеп сөйләшү, күрешү; *давно хотел с вами повидаться* — күптән сезнең белән (күрешеп сөйләшергә) очрашырга теләгән идем.

**ПО-ВИ'ДИМОМУ** *ввод. слово* — күрәсең, ахрысы, бугай, тесле, булса кирәк.

**ПОВИ'ДЛО** *ср. мн.* нет — повидло (изелгән җимештән шикәр белән кайнатып ясалган вареньесыман ашамлык).

**ПОВИДНЕ'ТЬ** *сов. безл. просторечи.*— яктыра башлау; *когда повиднело, отправились в путь* — яктыра башлагач, юлга чыктык.

**ПОВИ'ЗГИВАТЬ** *несов.*— чинаштыргалау.

**ПОВИЗЖА'ТЬ** *сов.*— чинап алу, чинап тору, чинап кую.

**ПОВИ'ЛИВАТЬ** *несов.*— к. повилять.

**ПОВИЛИ'КА** *ж. бот.*— кычыткан ефәге.

**ПОВИЛИ'ЧНЫЙ** — кычыткан ефәге...-ы; *повиличные семена* — кычыткан ефәге орлыклары.

**ПОВИЛЯ'ТЬ** *сов.*—1. (койрык) болгау, (койрык) болгап алу (мәсәлән, эт); 2. *разг. фам.* койрык болгау (юк-бар сәбәпләр табып төп эштән яки туры җаваптан читкә тайпылып вакытны уздыру).

**ПОВИНИ'ТЬСЯ** *сов. разг. устар.*— үз гаебеңне тану, икърар итү.

**ПОВИ'ННОСТНЫЙ** *офиц. право* — бушлай эшләү...-ы; алпавытка эшләү...-ы; *после отмены крепостного права между помещиком и крестьянством продолжали оставаться повинностные отношения* — крепостной право бетерелгәннән соң да, алпавыт белән крестьяннар арасында алпавытка бушлай эшләү мөнәсәбәтләре калган иде.

**ПОВИ'ННОСТЬ** *ж.*—1. *истор.* йөкләмә, түләүсез эшләү, бушлай эшләү йөкләмәсе (крестьяннарның алпавыт яки дәүләт идарәсе өчен түләүсез эшләү йөкләмәсе); 2. *офиц.* йөкләмә (гражданнарның дәүләт яки урындагы җәмәгатьчелек кирәкләре өчен эшләгән эше); *трудовая повинность* — хезмәт йөкләмәсе; *дорожная повинность* — юл төзәтү йөкләмәсе.

**ПОВИ'ННЫЙ**—1. *книж.* гаепле; *ни в чём неповинен* — бернәрсәдә дә гаепле түгел; 2. *устар. офиц.* бурычлы; тиешле; *по сему векселю повинен я заплатить 100 рублей* — шушы вексель буенча мин 100 сум түләргә тиешле. ◇ **Принести повинную или прийти (явиться) с повинной** — үзеңнең гаебеңне тану, икърар итү. **Повинную голову меч не сечёт** — иелгән башны кылыч кисмәс.

**ПОВИНОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов.* — буйсыну, баш ию.

**ПОВИНОВЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— буйсыну, буйсынучанлык.

**ПОВИНТИ'ТЬ** *сов.*— бераз борып кертү; *повинтить гайку* — гайканы бераз борып кертү.

**ПОВИСА'ТЬ** *несов.*— к. повиснуть.

**ПОВИСЕ'ТЬ** *сов.*— (бераз вакыт) эленеп тору, (бераз вакыт) асылынып тору.

**ПОВИ'СНУТЬ** *сов.*—1. асылыну, асылынып калу, сарылу; *ребёнок повис на шее* — бала муенга сарылды; 2. (*обвиснуть*) салы-

нып төшү. ◇ **Повиснуть в воздухе** *разг. перен.*— ярты юлда калу (берәр эш); *это дело повисло в воздухе* — бу эш ярты юлда калды, бу эш һавада асылынып калды (ягъни, бу эш эшкә ашмады).

**ПОВИТО'Й** — к. повитый.

**ПОВИТУ'ХА** *ж. простореч.*— кендек әбисе.

**ПОВИ'ТЫЙ** — уралган, чорналган.

**ПОВИ'ТЬ** I *сов.*—1. урау, чорнау; 2. (бераз) ишеп алу.

**ПОВИ'ТЬ** II *ж.*— к. поветь.

**ПОВИХНУ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— акылдан язу.

**ПОВЛА'СТВОВАТЬ** *сов. книж.*— хакимлек итеп алу, хакимлек итү.

**ПОВЛАЖНЕ'ТЬ** *сов.*— дымлану, дымланып китү.

**ПОВЛЕ'ЧЬ** *сов. книж.*— 1. *устар.* өстерәп алып китү; *его повлекли к воротам* — аны капкага таба өстерәп алып киттеләр; 2. китереп чыгару; *такое поведение может повлечь за собой всякие неприятности* — мондый кыланышның төрле күңелсезлекләр китереп чыгаруы мөмкин (төрле күңелсезлекләргә алып баруы мөмкин).

**ПОВЛЕ'ЧЬСЯ** *сов. книж. устар.*— китеп бару, юнәлү.

**ПОВЛИЯ'ТЬ** *сов.*— 1. тәэсир итү, йогынты ясау; 2. үз ягына аудару, ышандыру, күндерү.

**ПО'ВОД** I *м.*— сылтау; *повод для ссоры* — ызгышуга сылтау. ◇ **По поводу** — турында; **разговор шёл по поводу новой книги** — сөйләшү яңа китап турында барды.

**ПО'ВОД** II *м.*— тезген, йөгән тезгене; *вести лошадь в поводу* — атны тезгеннән тотып алып бару. ◇ **На поводу (быть)** *разг.*— (берәүнең) җырын җырлау.

**ПОВОДИ'ТЬ** I *несов.*— к. повести 5.

**ПОВОДИ'ТЬ** II *сов.*— 1. йөртү, йөртеп алу; *поводить взмыленную лошадь* — күбеккә батып тирләгән атны йөртеп алу; 2. йөртеп чыгу; *поводить утюгом по простыне* — утюг белән җәймә өстеннән йөртеп чыгу; 3. көттереп йөртү.

**ПОВОДИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— (бераз вакыт) бәйләнештә булып алу, дуслашып тору.

**ПОВОДКО'ВЫЙ** *спец.*— к. поводочный.

**ПОВОДО'К** *м.*— 1. *разг.* кыска тезген, тезгенчек; 2. *спец.* (*сворка*) эт муенсасы, бавы.

**ПОВОДО'ЧНЫЙ** *спец.*— тезген...-ы; *поводочный ремень* — тезген каешы.

**ПОВОДЫ'РЬ** *м.*— җитәкләп алып баручы; *слепой с мальчиком-поводырём* — җитәкләп алып баручы малай белән сукыр.

**ПОВОЕВА'ТЬ** *сов.*— 1. (бераз вакыт) сугышу, сугышып алу; 2. *перен. разг. шутл.* кычкырышып алу, ызгышып алу, сүз көрәштереп алу; *пассажиры повоевали из-за мест в вагоне* — пассажирлар вагонда урыннар өчен ызгышып алдылар; 3. *устар.* (*завоевать, покорить*) сугышып яулап алу, буйсындыру.

**ПОВОЗИ'ТЬ** *сов.*— 1. йөртеп чыгу, йөртеп алу; *повозили туристов по городу* — туристларны шәһәр буйлап йөртеп чыктылар; 2. ташу, ташып алу; *повозить сено* — печән ташып алу; 3. *простореч.* ташып бетерү; *хлеб с поля уже повозили* — игенне кырдан ташып бетерделәр инде.

**ПОВОЗИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. маташу, мәшәкатьләнү (нәрсәне булса да кайгыртып, мәшәкатьләнеп вакыт үткәрү); *много повозились с ним, пока он был болен* — ул авыру чакта аның белән шактый мәшәкатьләнделәр; 2. шаярып алу, шау-шу килеп алу; *дети повозились всласть* — балалар туйганчы шау-шу килеп алдылар; 3. баш вату; *часа два повозился над задачей* — мәсьәлә өстендә ике сәгать чамасы баш ватып утырдым.

**ПОВО'ЗКА** *ж.*— 1. көймәле арба, повозка; 2. арба.

**ПОВО'ЗОЧНЫЙ** — 1. арба...-ы; *повозочный кузов* — арба көймәсе; 2. кучер.

**ПОВО'ЙНИК** *м. устар.*— баш яулыгы

**ПОВО'ЛЖСКИЙ** — Идел буе...-ы; Идел буендагы; *поволжские леса* — Идел буе урманнары.

**ПОВОЛО'КА** *ж.*: **глаза с поволокой** — ягымлы моңсу күзләр.

**ПОВОЛОЧИ'ТЬ** *сов.*— өстерәп алып бару, сөйрәп алып бару; өстерәп алып китү.

**ПОВОЛОЧИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. әзрәк өстерәлеп бару, бераз сөйрәлеп бару; 2. *разг. устар.* (бераз вакыт хатын-кыз артыннан) йөрү, сөйрәлү.

**ПОВОЛО'ЧЬ** *сов. разг.*— 1. өстерәү, сөйрәп алып китү; 2. *простореч. вульг.* өстерәп алып китү, көчләп алып китү; *его поволокли в острог (Даль)* — аны төрмәгә өстерәп алып киттеләр.

**ПОВОЛО'ЧЬСЯ** *сов. простореч.*— 1. өстерәлү, өстерәлә-өстерәлә бару, сөйрәлеп бару; *подол поволокся по земле* — итәк җирдән өстерәлде; 2. *перен.* көчкә-көчкә китеп бару; *поволокся домой* — көчкә-көчкә өйгә китеп барды.

**ПОВО'ЛЬНИЧАТЬ** *сов. разг.*— (бераз вакыт) иркенәеп алу, азынып алу.

**ПОВОРА'ЧИВАТЬ** *несов.*— к. повернуть.

**ПОВОРА'ЧИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. повернуться; 2. *страд.* әйләндерелү. ◇ **Поворачивайтесь** *разг.* — тизрәк булыгыз, тизрәк эшләгез, тизрәк кыймылдагыз.

**ПОВОРОВА'ТЬ** *сов.*— 1. урлаштыргалап йөрү, урлап йөрү; 2. *разг.* урлау, урлап бетерү; урлап алып чыгу; *у меня поворовали много вещей* — минем күп әйберемне урладылар.

**ПОВОРО'ВЫВАТЬ** *несов. разг.*— урлаштыргалау; *сено-то из сарая поворовывают* — печәнне сарайдан урлаштыргалыйлар бит.

**ПОВОРОЖИ'ТЬ** *сов. разг. устар.*— күрәзәлек итеп алу, фал ачып алу.

**ПОВОРО'Т** *м.*— 1. әйләнеш, борылу; *поворот кругом* — тулы әйләнеш; *ловкий поворот* — җинел әйләнеш, җитез әйләнеш; 2. борылыш; *на повороте дороги* — юл борылышында; 3. *перен.* зур үзгәреш, борылыш; *коренной поворот деревни*

*к социализму* — авылның социализмга таба кискен борылышы. ◇ **От ворот поворот** *простореч. вульг.* — алдыннан артың яхшы; килгән юлың такыр түгелме; буш кул белән китү.

**ПОВОРОТИ'ТЬ** *сов. разг. простореч.*— к. повернуть.

**ПОВОРОТИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.*— к. повернуться.

**ПОВОРО'ТЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. (*подвижность, расторопность*) житезлек, җицел сөяклелек, терелек; 2. *тех. мор.* тиз борыла алучанлык; *поворотливость судна* — судноның тиз борыла алучанлыгы.

**ПОВОРО'ТЛИВЫЙ** *разг.*— житез, җицел сөякле, булдыклы.

**ПОВОРО'ТНЫЙ** — 1. *спец.* бору...-ы; *поворотный круг на железных дорогах* — тимер юлларда (паровозны) бору түгәрәге; 2. зур борылыш...-ы; зур үзгәреш...-ы; *поворотный момент в истории* — тарихта зур борылыш моменты.

**ПОВОРОШИ'ТЬ** *сов. разг.* — кузгату, кабартып алу, кабарту; *поворошить сено* — печәнне кабартып алу.

**ПОВОРЧА'ТЬ** *сов.*— мыгырдап алу, мыгырдау, сукранып алу, сукрану.

**ПОВРА'ТЬ** *сов. разг.*— күп ялганлау.

**ПОВРЕДИ'ТЬ** *сов.*— 1. зыян итү, зарар итү, зыян китерү; *курение повредит здоровью* — тәмәке тарту исәнлеккә зарар китерәчәк; 2. бозу, вату, җимерү; *повредить замок* — йозакны вату; *повредить рукопись небрежным обращением* — саксызлык белән кулъязманы бозу; 3. имгәтү; *повредить ногу при падении* — егылып аякны имгәтү.

**ПОВРЕДИ'ТЬСЯ** *сов.*— бозылу, ватылу, җимерелү. ◇ **Повредиться в уме** — акылдан язу.

**ПОВРЕЖДА'ТЬ** *несов.*— к. повредить 2.

**ПОВРЕЖДА'ТЬСЯ** *несов.*— к. повредиться.

**ПОВРЕЖДЕ'НИЕ** *ср.*— бозылу, сыну, ватылу; бозу, сындыру, вату.

**ПОВРЕЖДЁ'ННЫЙ** — бозык, бозылган, җимерек, җимерелгән, имгәнгән. ◇ **Повреждённый в уме** — акылдан язган.

**ПОВРЕМЕНИ'ТЬ** — бераз кичектерү, көтә төшү, сабыр итү; *повременить со взысканием долга* — бурыч түләтүне бераз кичектерү; *повремените, всё будет готово* — сабыр итегез, барысы да әзер булыр.

**ПОВРЕМЕ'ННИК** *м. устар.*— вакытлы матбугат.

**ПОВРЕМЕ'ННЫЙ** и *простореч.* **ПОВРЕМЁННЫЙ** — 1. вакытлы; *повременная печать* — вакытлы матбугат; 2. вакыт буенча...; сәгатьләп...; *повременная оплата* — сәгатьләп түләү (вакыт буенча түләү).

**ПОВСЕДНЕ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— көндәлек.

**ПОВСЕДНЕ'ВНЫЙ** — көндәлек..., көн саен була торган, һәр көн кабатлана торган; *повседневные заботы* — көндәлек мәшәкатьләр.

**ПОВСЕМЕ'СТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — һәр җирдә булу.

**ПОВСЕМЕ'СТНЫЙ** — һәр җирдә була торган, күп җирдә була торган.

**ПОВСЕЧА'СНЫЙ** *устар.*— даими, туктаусыз; *повсечасные заботы* — туктаусыз кайгыртулар, даими мәшәкатьләр.

**ПОВСКАКА'ТЬ** *сов.*— сикереп тору (берсе артыннан икенчесе).

**ПОВСКА'КИВАТЬ** *несов.*— к. повскакать.

**ПОВСТА'НЕЦ** *м.*— баш күтәрүче, восстаниедә катнашучы.

**ПОВСТА'НЧЕСКИЙ** — баш күтәрүче...-ы; баш күтәрүчеләр...-ы; баш күтәрү...-ы; *повстанческие отряды* — баш күтәрүчеләр отрядлары.

**ПОВСТА'НЧЕСТВО** *ср. мн.* нет — баш күтәрү хәрәкәте.

**ПОВСТРЕЧА'ТЬ** *сов. разг.*— очрату (уйламаганда).

**ПОВСТРЕЧА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— очрашу (көтмәгәндә).

**ПОВСЮ'ДУ** — һәркайда, һәр җирдә, бар җирдә, бөтен җирдә.

**ПОВТО'Р** *м. лит.*— кабатлау (художестволы сөйләмдә бер үк төрле авазларны яки сүз тезмәләрен билгеле бер эзлеклелектә кабатлау алымы).

**ПОВТОРЕ'НИЕ** *ср.*— 1. кабатлау, кабатлану; 2. (әдәби, музыкаль һ. б. әсәрләрдә) кабатлаулар, кабатланган сүзләр, кабатлана торган урын; *встречаются излишние повторения* — артык кабатлаулар очрый.

**ПОВТОРИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. кабатлау...-ы; *повторительные упражнения* — кабатлау күнегүләре; 2. икенче кат...; кабат...; *повторительный сбор военнообязанных* — гаскәри хезмәткә яраклыларны икенче кат җыю.

**ПОВТОРИ'ТЬ** *сов.*— кабатлау; *повторить движение* — хәрәкәтне кабатлау; *повторить урок* — дәресне кабатлау.

**ПОВТОРИ'ТЬСЯ** *сов.*— кабатлану; *старое не повторится* — узганнар кабатланмас.

**ПОВТО'РНЫЙ** — кабат эшләнгән, кабатланган, икенче кат эшләнгән; *повторная атака* — икенче кат ясалган атака.

**ПОВТОРЯ'ТЬ** *несов.*— к. повторить.

**ПОВТОРЯ'ТЬСЯ** *несов.*— повториться.

**ПОВЫВА'ТЬ** *несов. разг.*— вакыт-вакыт улау, улаштыргалау.

**ПОВЫ'СИТЬ** *сов.*— 1. күтәрә төшү, күтәрү, биегәйтү; *ветер повысил уровень воды* — җил суның биеклеген күтәрде; 2. көчәйтү, зурайту; арттыру; *повысим революционную бдительность!* — революцион сизгерлекне көчәйтик!

**ПОВЫ'СИТЬСЯ** *сов.*— 1. күтәрелү; *уровень воды повысился* — суның биеклеге күтәрелде; 2. зураю, көчәю; яхшыру; *качество повысилось* — сыйфат яхшырды.

**ПОВЫ'ТЬ** *сов.*— улап алу, (бераз вакыт) улап тору.

**ПОВЫША'ТЬ** *несов.*— к. повысить.

**ПОВЫША'ТЬСЯ** *несов.*—к. повыситься.

**ПОВЫ'ШЕ** *нареч.*— югарырак, өскәрәк.

**ПОВЫШЕ'НИЕ** *ср.*— 1. күтәрү, күтәрелү;

*повышение цен* — бәяләрнең күтәрелүе; 2. зураю, көчәю, зурайтылу, көчәйтелү; яхшыру, яхшырту; *повышение качества* — сыйфатны яхшырту; 3. *лит.* басым; 4. *лит.* (*первая часть периода*) теземнең беренче өлеше.

**ПОВЫ'ШЕННЫЙ** — күтәрелгән, күтәренке.

**ПОВЯЗА'ТЬ** *сов.*— 1. бәйләп кую (мәсәлән, яулыкны башка); 2. (бераз вакыт) бәйләп алу (мәсәлән, оекны, оекбашны).

**ПОВЯЗА'ТЬСЯ** *сов.*— 1. бөркәнү, ябыну; *повязаться платком* — яулык бөркәнү; 2. бәйләү; *повязаться передником* — алъяпкыч бәйләү.

**ПОВЯ'ЗКА** *ж.*— 1. бәйләвеч (башка яки җиңгә бәйләп куела торган тасма); 2. бинт.

**ПОВЯ'ЗЫВАТЬ** *несов.*— к. повязать 1.

**ПОВЯ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. повязаться 1; 2. *страд.* бәйләнү (мәсәлән, яулык).

**ПО'ВЯЗЬ** *ж. обл.*— к. повязка.

**ПОВЯ'НУТЬ** *сов.*— шиңү, шиңеп бету, пәжү, сулу.

**ПОГАДА'ТЬ** *сов.*— күрәзәлек итеп алу, фал ачып алу, багып алу.

**ПОГА'НЕЦ** *м. просторечь. презрит. бран.*— әшәке кеше, түбән кеше.

**ПОГА'НИТЬ** *несов. разг.*— 1. (*загрязнять*) пычрату, шакшылату; 2. *перен.* бозу; *поганить отношения* — араны бозу, мөнәсәбәтләрне бозу; 3. *перен. простореч.* (*ругать*) орышу, тиргәү.

**ПОГА'НИТЬСЯ** *несов. разг.*— пычрану, әшәкеләнү, шакшылану.

**ПОГА'НКА** *ж.*— агулы гөмбә, ашарга яраксыз гөмбә.

**ПОГА'НСТВО** *ср. разг. шутл.*— әшәкелек, пычраклык, намуссыз эш.

**ПОГА'НЫЙ** — 1. *разг.* әшәке, шакшы, пычрак, нәҗес; *поганое ведро* — пычрак чиләк; 2. ашарга ярамый торган; *поганые грибы* — ашарга ярамый торган гөмбәләр; 3. *простореч. бран.* әшәке; *поганый мальчишка* — әшәке малай; 4. *разг. фам.* начар, сыйфаты түбән; *поганое пальто* — начар пальто.

**ПОГА'НЫШ** *м.*— 1. *простореч. бран.* к. поганец; 2. *разг.* к. поганка.

**ПО'ГАНЬ** *ж. разг. презрит.*— шакшы, нәҗес, пычрак әйберләр.

**ПОГАСА'ТЬ** *несов. книж.*— к. гаснуть.

**ПОГАСИ'ТЬ** *сов.*— к. гасить.

**ПОГА'СНУТЬ** *сов.*— к. гаснуть.

**ПОГАША'ТЬ** *несов.* 1. *спец.*— кайтару, түләү; *погашать задолженность* — бурычны түләү; 2. сүндерү.

**ПОГАШЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *спец.*— кире кайтару, кайтару, түләү; *погашение долга* — бурычны кайтару, бурычны түләү.

**ПОГА'ШЕННЫЙ** — 1. сүндерелгән; 2. түләнгән, кире кайтарылган.

**ПО'ГИБ** *м. спец.*— бөгелеш, бөгелгән урын.

**ПОГИБА'ТЬ** *несов.*— һәлак булу.

**ПОГИ'БЕЛЬ** *ж. устар.* и *разг.*— к. гибель. ◇ **В три погибели** (гнуть) *разг.*— бик нык кысу, каты изү (мораль яктан).

**ПОГИ'БЕЛЬНЫЙ** *устар.*— һәлакәтле.

**ПОГИ'БНУТЬ** — к. гибнуть.

**ПОГИ'БШИЙ** — 1. беткән, һәлак булган; *погибший корабль* — һәлак булган корабль; 2. *простореч.* барып чыкмый торган, ышанычсыз; *это погибшее дело* — барып чыкмый торган эш, юкка чыккан эш; 3. *устар.* беткән, түбәнлеккә төшкән, эштән чыккан; *погибший человек* — беткән кеше, эштән чыккан кеше.

**ПО'ГИБЬ** *ж. спец.*— к. погиб.

**ПОГЛА'ДИТЬ** *сов.*— 1. сыйпап алу, сыйпау; *погладить по щеке* — яңактан сыйпап алу; 2. *разг.* үтүкләп алу, үтүкләү; *надо погладить бельё, пока есть время* — вакыт бар чакта, керләрне үтүкләп алырга кирәк; 3. *разг.* үтүкләп чыгу; *погладить всё бельё* — барлык керләрне үтүкләп чыгу. ◇ **Погладить по головке** *перен.*— баштан сыйпау (хуплау); *за это не погладят по головке* — моның өчен башыңнан сыйпамаслар.

**ПОГЛА'ДЫВАТЬ** *несов. разг.*— әз-әзләп кимерү, кимергәләү, кимерә бирү (мәсәлән, эт сөякне).

**ПОГЛА'ЖИВАТЬ** *несов.*— сыйпаштыргалау, сыйпап алгалау; *поглаживать больное колено* — авырткан тезне сыйпаштыргалау.

**ПОГЛАЗЕ'ТЬ** *сов. разг. фам.*— (бериникадәр вакыт) авыз ачып карап тору, зур кызыксыну белән (карап) күзәтеп тору.

**ПОГЛА'ТЫВАТЬ** *несов. разг.*— әз-әзләп йоту, вакыт-вакыт йоту, йоткалау.

**ПОГЛОДА'ТЬ** *сов.*— 1. кимереп бетерү; *собаки все кости поглодали* — этләр барлык сөякләрне кимереп бетерделәр; 2. кимереп алу, бераз кимерү.

**ПОГЛОТА'ТЬ** *сов. разг.*— йотып бетерү; *он поглотал все таблетки* — ул барлык таблеткаларны йотып бетерде.

**ПОГЛОТИ'ТЕЛЬНЫЙ** *спец.*— йоту...-ы; сеңдерү...-ы; *поглотительные свойства почвы* — туфракның сеңдерү үзенчәлекләре.

**ПОГЛОТИ'ТЬ** *сов.*— 1. *книж. ритор.* или *ирон.*— ашап бетерү, йотып җибәрү; 2. йоту, сеңдерү; *губка поглотила воду* — губка (болыт) суны сеңдерде (йотты); 3. *перен. книж. устар.* йоту; *море поглотило корабль* — диңгез корабльне йотты; 4. *перен.* алу, талап иту; *эта работа поглотила много времени и энергии* — бу эш бик күп вакыт һәм энергия алды. ◇ **Новая идея поглотила его** — яңа идея аны тулысынча үзенә тартты, ул тулысынча яңа идеягә бирелде. **Поглотить много книг** — бик күп китап укып чыгу. **Поездка поглотила много денег** — барып кайтуга күп акча тотылды. **Печь поглотила много топлива** — мичкә күп ягулык китте.

**ПОГЛОТИ'ТЬСЯ** *сов. книж.*— йотылу, йотылып бету, сеңү.

**ПОГЛОЩА'ТЬ** *несов.*— к. поглотить.

**ПОГЛОЩА'ТЬСЯ** *несов.*— к. поглотиться.

**ПОГЛУМИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. мыскыл иту,

хурлау, көлү; 2. мыскыл итеп алу, мәсхәрәләп алу, хурлап алу.

**ПОГЛУПЕ'ТЬ** *сов.*— аңгырая төшү, аңгыралану, ахмаклана төшү, ахмаклану.

**ПОГЛУПИ'ТЬ** *сов. разг. фам.*— акылсызлык эшләп ташлау, ахмаклык эшләп ташлау.

**ПОГЛЯДЕ'ТЬ** *сов.*— 1. карап алу, күз салу, күз төшереп алу, карап кую, карау; *поглядеть с удивлением* — гаҗәпсенеп карап кую; 2. карап тору; *поглядел с полчаса из окна* — ярты сәгатьләп тәрәзәдән карап торды. ◇ **Как я погляжу** — *разг.* күрәсең; карап-карап куям да, карап торам да; *какой же ты хвастун, как погляжу (Крылов)*— карап торам да, син бик мактанчык икәнсең.

**ПОГЛЯДЕ'ТЬСЯ** *сов.*— карап алу; *поглядеться в зеркало* — көзгегә карап алу.

**ПОГЛЯ'ДЫВАТЬ** *несов.* — караштыргалау, күз салгалау; *поглядывать за детьми* — балаларга күз салгалау.

**ПОГНА'ТЬ** *сов.*— 1. куу, куып алып китү, куып җибәрү; *погнать стадо в поле* — көтүне кырга куып җибәрү; 2. куып чыгару; *погнать кого-н. со службы* — берәр кешене хезмәттән куып чыгару; 3. куа башлау; *погнать лошадь вскачь* — атны чаптырып куа башлау.

**ПОГНА'ТЬСЯ** *сов.*— куу, куа бару, куып бару, куып китү; *собаки погнались за зайцем* — этләр куянны куып киттеләр; *погнаться за деньгами* — акча артыннан куу. ◇**За двумя зайцами погонишься, не одного не поймаешь** — ике көймәнең койрыгын тотып булмый.

**ПОГНЕ'ВАТЬСЯ** *сов. устар.*— ачуланып алу, ярсып алу. ◇ **Не погневайся** — ачуланма, гафу ит.

**ПОГНЕВИ'ТЬ** *сов. устар.*— ачуландыру, ярсытып җибәрү.

**ПОГНИ'ТЬ** *сов.*— 1. черү, әзрәк черү; *бревно погнило от лежания на земле* — бүрәнә җирдә ятып әзрәк черегән; 2. череп бетү; *грибы погнили в земле* — гөмбәләр туфракта череп беткәннәр; 3. чери төшү; *пусть куча листьев погниёт ещё* — яфраклар өеме тагы да чери төшсен әле.

**ПОГНОИ'ТЬ** *сов.*— 1. (бераз вакыт) черетеп алу; *погноить ещё навоз в кучах* — тиресне өемнәргә өеп тагы да бераз черетеп алу; 2. *перен. устар. (подержать в заточении)* ябып тоту, авыр шартларда тоту, черетү (төрмәдә, сөргендә).

**ПОГНУ'ТЬ** *сов.*— 1. бөгү, кәкрәйтү; 2. бераз бөгеп тору.

**ПОГНУ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. бөгелү, кәкрәю; *ось погнулась* — күчәр кәкрәйгән; 2. *перен. (поддаться)* бирешү, бирелү.

**ПОГНУША'ТЬСЯ** *сов.*— җирәнү, чиркану; *не погнушайтесь откушать у нас* — рәхим итеп ашагыз, җирәнмәгез.

**ПОГОВА'РИВАТЬ** *несов. разг.*— сөйләшкәләү, сөйләштергәләү; *поговаривают об отъезде* — китү турында сөйләшкәлиләр.

**ПОГОВОРИ'ТЬ** *сов.*— 1. сөйләшеп алу, бераз сөйләшеп алу; *поговорили на разные темы* — төрле темаларга сөйләшеп алдылар; 2. киңәшеп алу, гәпләшеп алу; *поговорить о дальнейшей работе* — киләчәк эш турында киңәшеп алу.

**ПОГОВО'РКА** *ж.*— 1. әйтем, халык сүзе; 2. *(пословица)* мәкаль; 3. *обл.* имеш-мимешләр, төрле сөйләшүләр; *была об этом поговорка* — бу турыда имеш-мимешләр булган иде; 4. *обл.* әйтелеш, сөйләш; *ардатовца всегда по поговорке узнаешь (Даль)*— Ардатов шәһәре кешесен һәрвакыт сөйләшеннән белеп була.

**ПОГО'ДА** *ж.*— 1. һава торышы, һава хәле, һава; *дождливая погода* — яңгырлы һава; 2. *обл.* начар һава, көчле җил, яңгыр; *разгулялась погода* — һава начарайды; *на море погода поднялась (Даль)*— диңгездә көчле җил күтәрелде.

**ПОГО'ДИТЬ** *несов. безл. обл.*— кар яву, яңгыр яву; *на дворе погодит* — тышта кар ява.

**ПОГОДИ'ТЬ** *сов. разг.*— көтеп тору, бераз көтү, туктап тору, сабыр итү. ◇ **С этим делом надо погодить** — бу эштә ашыгырга ярамый. **Немного погодя** — бераз торгач, бераздан соң.

**ПОГО'ДКА** *ж. разг.*— һава, һава торышы, һава хәле.

**ПОГО'ДНЫЙ** I *книж.* — ел саен алып барыла торган, еллык...; *погодные записи* — еллык язмалар.

**ПОГО'ДНЫЙ** II — 1. *спец.* һава...-ы; *погодные особенности весны* — язның һава үзенчәлекләре; *погодные условия* — һава шартлары; 2. *обл.* яңгырлы, бозык; *на дворе погодно* — тышта һава бозык; 3. *обл.* аяз; *погодная пора* — аяз көннәр, аяз вакыт.

**ПОГО'ДОК** *м.*— бер яшь(кә) кече; *сестра — мне погодок* — сеңелем миннән бер яшь(кә) кече.

**ПОГО'ЖИЙ** — аяз; *погожий день* — аяз көн.

**ПОГОЛО'ВНО** *нареч.*— баштанаяк; барысын да, бөтенесен дә, берсен дә калдырмыйча, барысы да.

**ПОГОЛО'ВНЫЙ** — 1. баш исәбеннән...; берәмләп...; *поголовный счёт скота* — терлекләрне берәмләп санап чыгу; 2. барсын да... берсен дә калдырмыйча...; *поголовное обучение молодежи* — яшьләрнең берсен дә калдырмыйча укыту.

**ПОГОЛО'ВЬЕ** *ср. мн.* нет — саны, баш исәбе; *рост поголовья молочного скота* — сөт бирә торган терлекләрнең саны арту; *конское поголовье* — атлар саны.

**ПОГОЛОДА'ТЬ** *сов.* — ач торып алу, бераз ач тору, бераз ачыгу.

**ПОГОЛОСИ'ТЬ** *сов.*— акырып елап алу.

**ПОГОЛУБЕ'ТЬ** *сов.*— зәңгәрләнә төшү, күгелҗемләнә төшү.

**ПОГО'Н** *м.*— 1. *обл.* и *устар.* куа бару, куып бару; 2. погон; *генеральские погоны* — генерал погоннары; 3. *спец.* (берәр әйберне җилкәгә асу) каешы; *погон у охотничьего ружья* — аучы мылтыгының (җилкәгә асу) каешы; 4. *обл.* начар аракы, аракы төбе.

**ПОГО'НКА** *ж. обл.*— 1. куа бару, куып бару; *броситься в погонку* — артыннан куа башлау; 2. түп, калдык.

**ПОГО'ННЫЙ** *спец. устар.*— буйга үл-

чәү...-ы; *погонная сажень* — буйга үлчәү сажены.

**ПОГО'НЩИК** *м.*— куучы, куып баручы.

**ПОГО'НЬ** *ж. мн.* нет, *обл.* и *устар.*— к. погоня.

**ПОГО'НЯ** *ж. мн.* нет — 1. (*преследование бежавшего)* куа бару, куып бару; 2. куучылар төркеме; *за ним по пятам мчалась погоня* — аның артыннан ук куучылар төркеме йөгерә иде; 3. *перен.* куу; *погоня за славой* — шөһрәт артыннан куу.

**ПОГОНЯ'ЛКА** *ж.*— 1. *простореч. (то, чем погоняют)* кугыч (чыбыркы, камчы, чыбык); 2. *тех.* соса.

**ПОГОНЯ'ТЬ** I *несов.*—1. куу, бераз куа төшү, куалау; *погонять лошадей кнутом* — атларны чыбыркы белән куу; 2. *перен. разг.* ашыктыру; *не погоняй меня, я успею сделать до завтра* — ашыктырма мине, мин иртәгә хәтле эшләп чыгармын.

**ПОГОНЯ'ТЬ** II *сов.*—(берникадәр вакыт) куып бару, куу, куып йөртү, йөртү. ◇ **Погонять голубей** — күгәрчен куу, күгәрчен очыру.

**ПОГОНЯ'ТЬСЯ** I *несов.*— куылу.

**ПОГОНЯ'ТЬСЯ** II *сов.* — куып йөрү; *собака погонялась за курами* — эт тавыкларны куып йөрде.

**ПОГОРА'ТЬ** *несов.*— к. погореть.

**ПОГОРЕВА'ТЬ** *сов.*— бераз кайгырып алу, бераз көенеп алу, бераз хәсрәтләнеп алу.

**ПОГОРЕ'ЛЕЦ** *м.*— мөлкәте, (өе) янган кеше; *помощь погорельцам* — өе янган кешеләргә ярдәм.

**ПОГОРЕ'ЛЫЙ** *обл.*— янган, янып беткән; *погорелое место* — янган урын. ◇ **На погорелое** *обл. простореч.*— мөлкәте янган кешеләргә ярдәмгә.

**ПОГОРЕ'ТЬ** *сов.*— 1. янып бетү (янгында); 2. мөлкәте (өе) яну; 3. *спец.* кибеп бетү; корып бетү; *цветы в саду погорели* — бакчада чәчәкләр көеп беткән; 4. черү, кызу, яну; *мокрое сено погорело в стогу* — кибәндә юеш печән кызган; 5. янып тору; *свеча погорела и погасла* — шәм янып торды да сүнде; 6. сулкылдап тору; *палец погорел и перестал* — бармак сулкылдап торды да басылды; 7. кызарып китү; *у меня щёки погорели от стыда* — оятымнан яңакларым кызарып китте.

**ПОГОРЯЧИ'ТЬСЯ** *сов.*— бераз кызу, бераз ярсу, бераз кызып алу, бераз ярсып алу; *погорячился немного и успокоился* — бераз кызып алды да тынычланды.

**ПОГО'СТ** *м.*— 1. авыл зираты, авыл каберлеге; 2. *устар.* зират чиркәве; 3. авыллардан ерак постоялый двор.

**ПОГОСТИ'ТЬ** *сов.*— кунак булу, кунак булып алу, кунак булып тору.

**ПОГРА'БИТЬ** *сов. разг.*— талау, талап йөрү.

**ПОГРАНИ'ЧНИК** *м.*— пограничник, чик сакчысы (ил чиген саклаудагы гаскәри).

**ПОГРАНИ'ЧНЫЙ** — чик буендагы, чик буе...-ы; *пограничный район* — чик буе районы.

**ПО'ГРЕБ** *м.*— 1. кар базы, нәүрәп, баз; *молоко в погребе* — сөт кар базында; 2. *спец.* эчемлек саклау урыны; 3. *устар.* эчемлекләр сату һәм шунда ук эчү урыны; 4. *перен. разг.* эчемлекләр запасы; *у него хороший погреб* — аның эчемлекләр запасы зур. ◇ **Пороховой погреб** — 1. дары базы (дары саклау базы); 2. *перен. книж.* сугыш учагы.

**ПОГРЕБА'ЛЬНЫЙ** *книж.* — күмү...-ы; мәет күмү..-ы; *погребальный обряд* — мәет күмү йоласы.

**ПОГРЕБА'ТЬ** *несов. книж.*— күмү, жирләү.

**ПОГРЕБА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.*— күмелү, жирләнү.

**ПОГРЕБЕ'НИЕ** *ср. книж.*— к. погребать.

**ПОГРЕБЕ'Ц** *м. устар.*— юл азыклары сандыгы.

**ПОГРЕБНО'Й** *спец.* — эчемлек подвалы...-ы; *погребное хозяйство в винодельческих районах* — эчемлек хәзерләү районнарында эчемлек подвалы хуҗалыгы.

**ПОГРЕБЩИ'К** *м. устар.*— эчемлек подвалы хуҗасы.

**ПОГРЕВА'ТЬ** *несов. разг.* — җылыту, җылыткалау, вакыт-вакыт җылыту; *солнышко уже начинает погревать* — кояш җылыта башлый инде.

**ПОГРЕ'ЗИТЬ** *сов.*— хыялга чуму, хыялга чумып алу.

**ПОГРЕМЕ'ТЬ** *сов.*— күкрәү, күкрәп тору, гөрелдәп тору; *гром не долго погремел* — күк озак күкрәмәде. ◇ **Его слава не долго погремела** — аның даны озакка бармады.

**ПОГРЕМО'К** I *м. разг.* — шалтыравык (уенчык).

**ПОГРЕМО'К** II *м. бот.*— этәч кикриге (үсемлек).

**ПОГРЕМУ'ШКА** *ж.* — 1. шалтыравык (балалар уенчыгы); 2. *перен.* әһәмиятсез нәрсә, шалтыравык; 3. шөлдер.

**ПОГРЕСТИ'** I *сов. книж.* — мәет күмү, җирләү; 2. яшерү; күмү (гомумән берәр нәрсәне); 3. *перен.* оныту, онытып бетерү; *прошлое навек погребено* — үткән тормыш мәңгегә онытылган.

**ПОГРЕСТИ'** II *сов.*— 1. бераз ишеп алу, бераз ишү; *погреби правым веслом* — уң ишкәк белән бераз иш; 2. тырма белән җыю; *погрести сена* — печәнне тырма белән җыю.

**ПОГРЕ'ТЬ** *сов.*— җылытып алу, җылыту. ◇ **Погреть руки** — к. греть.

**ПОГРЕ'ТЬСЯ** *сов.*— җылынып алу.

**ПОГРЕША'ТЬ** *несов. книж.* — к. грешить 2.

**ПОГРЕШЕ'НИЕ** *ср. устар.*— гөнаһ, хата, язык.

**ПОГРЕШИ'ТЬ** *сов.*— 1. *книж.* ялгышу, бозу; *погрешить против истины* — чынбарлыкны бозу; 2. гөнаһ кылу; *довольно он погрешил в молодости* — яшь чагында ул җитәрлек гөнаһ кылды; 3. *разг. (возвести на кого-н. что-н.)* юкка гаепләү, яла ягу.

**ПОГРЕ'ШНОСТЬ** *ж.*— хата, төгәлсезлек, ялгышлык, кимчелек, җитешсезлек; *есть ряд погрешностей в выводах* — нәтиҗәләрдә кайбер төгәлсезлекләр бар.

**ПОГРОЗИ'ТЬ** *сов.*— куркыту, янау; *драгун погрозил ему пистолетом* (*Герцен*)— драгун аңа пистолет белән янады.

**ПОГРОЗИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.*— янау, куркыту, бармак янау, бармак янап кую.

**ПОГРО'М** *м.*— **1.** погром (капиталистик илләрдә хакимлек итүче сыйныфлар һәм хөкүмәт тарафыннан оештырылган милли-шовинистик чыгыш — аерым милләт халыкларының бер өлешен үтерү, талау; *еврейские погромы в царской России* — патша Россиясендә еврей погромнары; *армянские погромы в султанской Турции* — солтан Төркиясендә әрмән погромнары); **2.** *устар.* талау, кырып бетерү, җимерү, тар-мар итү; *погром городов Батыем* — Батыйның шәһәрләрне җимерүе.

**ПОГРОМИ'ТЬ** *сов.*— **1.** *устар.* погром ясау, талау, җимерү, кырып бетерү; **2.** (берникадәр вакыт) талап йөрү.

**ПОГРО'МНЫЙ** — погромга чакыру...-ы; *погромные выступления*—погромга чакыру чыгышлары.

**ПОГРО'МЩИК** *м. презрит.*— **1.** погромчы, талаучы; **2.** үтә реакционер, үтә шовинист.

**ПОГРОМЫХА'ТЬ** *сов. разг.*— к. погрохотать.

**ПОГРОМЫ'ХИВАТЬ** *несов. разг.* — гөрелдәштергәләү, күкрәштергәләү, күкрәп-күкрәп алу.

**ПОГРОХА'ТЫВАТЬ** *несов. разг.*— к. погромыхивать.

**ПОГРОХОТА'ТЬ** *сов.*— күк күкрәү, күкрәп тору, гөрелдәп тору; күкрәп-күкрәп алу, гөрелдәп-гөрелдәп алу, гөрселдәү; *гром погрохотал недолго* — күк күкрәү озакка бармады.

**ПОГРУБЕ'ЛЫЙ** *разг.*— дорфаланган, тупасланган, тупас; *погрубелая кожа* — тупасланган тире.

**ПОГРУБЕ'ТЬ** *сов.*— тупаслану, дорфаланып китү.

**ПОГРУБИ'ТЬ** *сов. разг.*— тупас сүз әйтү, начар сүз әйтү.

**ПОГРУЖА'ТЬ** *несов.* — к. погрузить.

**ПОГРУЖА'ТЬСЯ** *несов.*— **1.** к. погрузиться; **2.** *страд.* батырылу, чумдырылу; **3.** *страд.* төялү.

**ПОГРУЗИ'ТЬ** *сов.*— **1.** батыру, күмү, тыгу; *погрузить в воду* — суга батыру; *погрузить ноги в песок* — аякларны комга күмү; **2.** төяү, йөк төяү; *погрузить мебель на грузовик* — мебельне йөк машинасына төяү; *погрузить баржу* — баржага йөк төяү. ◇ Погрузить в сон — йокыга талдыру. Погрузить в отчаяние — өметсезлеккә төшерү.

**ПОГРУЗИ'ТЬСЯ** *сов.* — **1.** бату, чуму; *ведро погрузилось в воду* — чиләк суга чумды; *город погрузился в темноту* — шәһәр караңгылыкка чумды; *я погрузился в размышления* — мин уйга баттым; *раскрыл книгу и погрузился в чтение* (*Чехов*) — китапны ачты да укуга чумды; **2.** төялү, утыру; *дивизия погрузилась для отправки на фронт* —дивизия фронтка китәр өчен машиналарга төялде.

**ПОГРУ'ЗКА** *ж. мн.* нет, *спец.* — (йөк) төяү; *погрузка ящиков на пароход* — ящикларны пароходка төяү; *погрузка войск в эшелоны* — гаскәрләрне эшелоннарга төяү.

**ПОГРУЗНЕ'ТЬ** *сов.*— авыраю, авырая төшү.

**ПОГРУ'ЗНУТЬ** *сов. обл.*— бату, чуму, күмелү.

**ПОГРУ'ЗОЧНЫЙ** *спец.*— йөк төяү...-ы; *погрузочные механизмы* — йөк төяү механизмнары.

**ПОГРУ'ЗЧИК** *м. спец.*— к. грузчик.

**ПОГРУСТИ'ТЬ** *сов.*— бераз күңелсезләнеп алу, бераз ямансылап алу, пошынып алу, сагышланып алу.

**ПОГРЫ'ЗТЬ** *сов.*— **1.** кимереп алу, әзрәк кимерү; *собака погрызла кость и бросила* — эт сөякне әзрәк кимерде дә ташлады; **2.** *разг.* кимерү, кимереп бозу; *мыши погрызли переплёты у книг* — тычканнар китап тышларын кимереп бозганнар. ◇ Погрызть семечки — көнбагыш яру.

**ПОГРЫ'ЗТЬСЯ** *сов. разг.*— **1.** талашу; *собаки погрызлись и разошлись* — этләр бераз талаштылар да як-якка киттеләр; **2.** чәйнәшү; *собаки погрызлись до крови* — этләр канга батканчы чәйнәштеләр.

**ПОГРЯЗА'ТЬ** *несов. книж.*— к. погрязнуть.

**ПОГРЯ'ЗНУТЬ** *сов. книж.*— **1.** бату; *колёса погрязли в размытой дождём глине* — тәгәрмәчләр яңгыр белән йомшарган балчыкка баттылар; **2.** *перен. неодобр.* төшү, бату; *погрязнуть в разврате* — бозыклыкка төшү, азгынлыкка бату; *погрязнуть в невежестве* — наданлыкка бату; *погрязнуть в долгах* — бурычка бату.

**ПОГУБИ'ТЕЛЬ** *м. устар.* и *обл.*— һәлак итүче.

**ПОГУБИ'ТЬ** *сов.*— һәлак итү, башын ашау, башына җитү; *он погубил её* — ул аның башын ашады, башына җитте, ул аны һәлак итте.

**ПОГУДЕ'ТЬ** *сов.*— гүләү, гүләп алу, сызгырту, сызгыртып алу, кычкырту, кычкыртып алу, бераз кычкыртып тору.

**ПОГУ'ДКА** *ж. обл.*— **1.** көй; **2.** такмак, такмаза. ◇ Какова погудка, такова и пляска — чиләгенә күрә капкачы; көенә күрә биюе. Старая погудка на новый лад — иске авыздан яңа сүз.

**ПОГУ'ЛИВАТЬ** *несов. разг.*— йөрештергәләү; *погуливать на солнышке* — кояшта йөрештергәләү; **2.** типтергәләү, әйттергәләү; *парень начал погуливать* — егет типтергәли башлады.

**ПОГУЛЯ'НКИ** *ед.* нет, *обл.*— эштән буш көннәр; *заходите к нам на погулянках* — эштән буш көннәрдә безгә керегез.

**ПОГУЛЯ'ТЬ** *сов.*— **1.** бераз йөреп алу, бераз йөрү, бераз йөреп кайту; *погулять перед обедом* — көндезге аш алдыннан йөреп алу; *дети погуляли* — балалар бераз йөреп кайттылар; **2.** бераз күңел ачып алу, күңел ачу, әйттерү; *погулять на свадьбе* — туйда күңел ачу; *а с денежонками, сам знаешь, и попьёшь, и погуляешь* (*Ершов*) — акча булгач, үзең беләсең, эчәсең дә, әйттерәсең дә.

**ПОГУСТЕ'ТЬ** *сов. разг.*— куера төшү (мәсәлән, кесәл).

**ПОГУТО'РИТЬ** *сов. обл.*— сөйләшеп алу, гәпләшеп алу.

**ПОД** I *м.*— мич төбе.

**ПОД** II *предлог с вин. п.*— 1. астына; *поставить корзинку под стол* — кәрзинне өстәл астына кую; 2. астыннан; *надеть джемпер под пиджак* — пиджак астыннан джемпер кию; 3. ...-га таба, тирәсенә; *Пётр двинул полки под Полтаву* — Пётр үзенең полкларын Полтавага таба (Полтава янына) юнәлтте; 4. ...-га; *отдать под суд* — судка бирү; *заключить под стражу* — төрмәгә ябу; *попасть под чьё-н. влияние* — берәр кешенең тәэсиренә бирелү; 5. ...-га таба, алдыннан; *под вечер* — кичкә таба (кич якынлашкач); *под праздник* — бәйрәм алдыннан; *под осень* — көзгә таба (көз якынлашкач); 6. ... яшьләр чамасы; *ей под сорок* — аңа кырык яшьләр чамасы; 7. ...-га охшатып; *окрасить под красное дерево* — кызыл агачка охшатып буяу; *стихи под Блока* — Блок шигырьләренә охшатып язылган шигырьләр; 8. *устар.* каршы; *ходили под турку* — төрекләргә каршы бардылар; 9. ...-дан; *держать бочку под дно* — мичкәне төбеннән тоту; *рубить дерево под корень* — агачны төбеннән кисү. ◇ **Бочка предназначена под мёд** — мичкә бал салу өчен билгеләнгән. **Назначить участок под клевер** — клевер чәчү өчен участок билгеләү. **Взять деньги под расписку** — расписка биреп акча алу. **Получить что-н. под залог** — әйберләрне залогка салып берәр нәрсә алу. **Уснул под разговор** — сөйләшүне тыңлый-тыңлый йокыга китте. **Попасть под дождь** — яңгырга эләгү. **Спрятать под замок** — бикләп кую. **Взять под руки** — култыклау, култыклап алу.

**ПОД** III *предлог с твор. п.*— 1. астында, астыннан; *самолёт летает под облаками* — самолёт болытлар астында очып йөри; *самолёт летит под облаками* — самолёт болытлар астыннан очып бара; 2. тирәсендә(ге), янында(гы), якынында(гы); *жить под Москвой* — Москва тирәсендә (якынында) тору; *битва под Полтавой* — Полтава тирәсендәге сугыш; 3. ...-да; *быть под руководством кого-н.*— берәр кешенең җитәкчелегендә булу; *под влиянием гнева* — ачу тәэсирендә; *под наблюдением врача* — врач карамагында; 4. *устар.* ...-га каршы; *бывали под туркой* — төрекләргә каршы сугышларда булдылар. ◇ **Вещи лежат под замком** — әйберләр бикләп куелган (мәсәлән, шкафка). **Хранить ценности под ключом** — кыйммәтле әйберләрне бикләп саклау. **Сарай под сеном** — печән тутырылган сарай. **Пароход под советским флагом** — совет флагы күтәргән пароход. **Папиросы под новой маркой** — яңа маркалы папирос. **Статья под моим именем** — минем имзам куелган мәкалә. **Что надо понимать под этим термином?**— бу терминн нәрсәне белдерә?

**ПОДАВА'ЛЬЩИК** *м.*, **ПОДАВА'ЛЬЩИЦА** *ж.*— биреп торучы, ташып торучы (1. *спец.* ашханәләрдә аш йөртеп, биреп торучы официант; 2. *спец.* производствода эшкәртелү урынына материал ташып торучы; 3. *спорт.* лапта уенында туп биреп торучы).

**ПОДАВА'ТЬ** *несов.*— 1. к. подать; 2. *спец.* (ашны) хәзерләп бирү; *рыбу подают с соусом* — балыкны соус белән хәзерләп бирәләр. ◇ **Подавать надежды** — өмет бирү, өметле булу.

**ПОДАВА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. податься; 2. *страд.* (аш) хәзерләнеп бирелү.

**ПОДАВИ'ТЬ** *сов.*— 1. бераз басып тору, бераз кысып тору; *подавить больное место* — авырткан урынны бераз (басып) кысып тору; 2. таптату, таптау; *сорвавшиеся с привязи лошади подавили немало народу* — бәйләп ычкынган атлар күп кешене таптадылар; 4. бастыру; *подавить мятеж* — фетнәне бастыру; 5. басу; *подавить страх* — куркуны басу; *подавить чувство боли* — авыртуны басу; 6. күңелен төшерү; *его подавила неудача* — уңышсызлык аның күңелен төшерде; 7. *перен книж.* (саны ягыннан) арту, артып китү; күбәеп китү; *русские книги в библиотеке совершенно подавили своей численностью иностранные* — китапханәдә рус китапларының саны чит ил китапларының санынннан әллә никадәр артты; 8. *книж.* искитәрү, шаккатыру, бик нык тәэсир итү; *подавить всех своим исключительным успехом* — үзенең гадәттән тыш зур уңышың белән башкаларның исен китәрү.

**ПОДАВИ'ТЬСЯ** *сов.* — төелү (коры ашны ашаганда); тамагына утыру, бугазына тыгылу; *подавиться костью* — тамакка сөяк утыру.

**ПОДАВЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — бастыру, басу; *подавление мятежа* — фетнәне бастыру.

**ПОДА'ВЛЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— күңел төшенкелеге, рух төшенкелеге, кәеф начарлык, кәеф төшенкелеге, кәефсез булу, боек булу; *его подавленность действовала на всех* — аның кәефсез булуы барысына да тәэсир итә иде.

**ПОДА'ВЛЕННЫЙ** — 1. басылган, бастырылган; 2. ишетелер-ишетелмәс, томаланган, томаланып калган; *подавленный стон* — ишетелер-ишетелмәс ыңгырашу; 3. төшенке, күңелсез; *подавленное настроение* — төшенке күңел.

**ПОДА'ВЛИВАТЬ** *несов.*— кыскалау.

**ПОДАВЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. подавить 4, 5, 7, 8.

**ПОДАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— бастырылу.

**ПОДАВЛЯ'ЮЩИЙ** — 1. баса торган; 2. иң зур; *подавляющее большинство* — иң зур күпчелек.

**ПОДА'ВНО** *нареч. разг.*— бигрәк тә, күптән, әлбәттә.

**ПОДА'ГРА** *ж. мн.* нет — подагра (кулаяк буыннары, бигрәк тә бармак буыннары сызлау авыруы).

**ПОДА'ГРИК** *м.*, **ПОДАГРИ'ЧКА** *ж.*— подагра белән авыручы.

**ПОДАГРИ'ЧЕСКИЙ** подагра...-ы; *подагрические явления* — подагра күренешләре.

**ПОДА'ЛБЛИВАТЬ** *несов.*— чокыштыру, чокыштыргалау.

**ПОДА'ЛЬШЕ** *нареч.*— ераграк, бик ерак.

**ПОДАРИ'ТЬ** *сов.*— бүләк итү, бүләк итеп бирү.

**ПОДА'РОК** *м.*— бүләк, сөенче (шатлыклы хәбәр өчен бирелгән бүләк); ядкарь (истәлек өчен бирелгән бүләк).

**ПОДА'РОЧНЫЙ** — бүләк итеп бирерлек...; бүләклек...; *подарочные изделия* — бүләклек әйберләр.

**ПОДА'ТЕЛЬ** *м.*, **ПОДА'ТЕЛЬНИЦА** *ж. офиц.*— бирүче, тапшыручы; *прошу выдать книгу подателю этого письма* — китапны шушы хатны тапшыручыга бирүегезне үтенәм.

**ПОДА'ТЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. *(о человеке)* юл куючанлык, сүз тыңлаучанлык, иплелек; 2. *(о веществе)* үзлелек, эластиклык, пешелек.

**ПОДА'ТЛИВЫЙ** — 1. *(человек)* юл куючан, сүз тыңлаучан, ипле; 2. *(вещество)* үзле, эластик, пеше.

**ПОДАТНО'Й** *истор.*— 1. салым җыю...-ы; *податной инспектор* — салым җыю инспекторы; 2. салым түләргә тиешле; *податные сословия* — салым түләргә тиешле сословиеләр.

**ПО'ДАТЬ** *ж. истор.*— ясак, имана, салым (крестьян һәм мещаннардан җан башыннан җыела торган салым).

**ПОДА'ТЬ** *сов.*—1. бирү, тапшыру, китереп бирү, илтеп бирү; 2. илтеп җиткерү, ташып (күчереп, китереп җиткереп) өлгертү; *тыл подал во-время снаряды на фронт* — тыл снарядларны үз вакытында фронтка китереп җиткерде; 3. кертү, кертеп җибәрү; *подать патрон в канал ствола* — патронны мылтык көпшәсе каналына кертеп җибәрү; 4. этәреп җибәрү; *подать бревно в сторону* — бүрәнәне бер якка этәреп җибәрү; 5. бору, авыштыру; *подать корпус влево* — гәүдәне сулга бору; 6. сузу; *подать руку вперёд* — кулны алга таба сузу; 7. чигендерү; *подать лошадь назад* — атны артка таба чигендерү; 8. күрсәтү; *подать помощь* — ярдәм күрсәтү; *подать пример* — үрнәк күрсәтү. ◇ **Кушанье подано** — аш өстәлгә куелган. **Когда подали лошадь, уже всходило солнце** — атны китергәндә, кояш чыгып килә иде инде. **Подать в отставку** — отставкага чыгу. **Подать мысль** — фикер әйтү (бирү). **Рукой подать** — якында гына, бик якын.

**ПОДА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *разг.* читкәрәк китү, (кузгалып) чигенү, тайпылу; *толпа подалась в сторону* — халык төркеме бер якка тайпылды; 2. кузгалу; *ворота подались под напором* — этәрә торгач капка кузгалды; 3. *разг.* янтаю, кыйшаю, җимерелә башлау; *свод подался* — гөмбәз кыйшайган; 4. *простореч. шутл.* китеп бару, юнәлү; *податься на юг* — көньякка китеп бару; 5. *разг.* күнү, риза булу; *долго он крепился и, наконец, подался* — ул шактый гына бирешми торды да соңыннан риза булды. ◇ **Податься некуда** *разг.*— берни дә эшләп булмый.

**ПОДА'ЧА** *ж.*— к. подать. ◇ **Штемпель места подачи** — хат, телеграмма һ. б. җибәргән урынның штемпеле.

**ПОДА'ЧКА** *ж. разг.*— 1. этка (яки терлеккә) ташланган ашамлык кисәге; 2. *пренебр.* сәдака.

**ПОДАЯ'НИЕ** *ср. устар.*— хәер-сәдака, хәер.

**ПОДБА'ВИТЬ** *сов.*— бераз өстәү, азрак өстәп җибәрү, өсти төшү, тагы да өстәү.

**ПОДБА'ВИТЬСЯ** *сов. разг.*— өстәлә төшү, бераз өстәлү, тагы да өстәлү.

**ПОДБА'ВКА** *ж. мн.* нет, *разг.*— к. подбавить.

**ПОДБАВЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. подбавить.

**ПОДБАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— к. подбавиться.

**ПОДБА'ЛТЫВАТЬ** *несов.*— к. подболтать.

**ПОДБА'ЛТЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— әзрәк болгатып җибәрелү.

**ПОДБЕГА'ТЬ** *несов.*— к. подбежать.

**ПОДБЕЖА'ТЬ** *сов.*— 1. (янына) йөгереп килү; *подбежать к дому* — өй янына йөгереп килү; 2. (берәр нәрсә астына) йөгереп керү; *собака подбежала под мост* — эт күпер астына йөгереп керде.

**ПОДБЕ'ЛИВАТЬ** *несов.*— к. подбелить.

**ПОДБЕ'ЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. агартып җибәрелү, бераз акшарлап алыну, агартыла төшү; 2. *разг.* әзрәк сөт салып җибәрелү; әзрәк каймак салып җибәрелү (берәр төрле ашка).

**ПОДБЕЛИ'ТЬ** *сов.*— 1. бераз агартып алу, бераз акшарлап алу; агарта төшү; *подбелить стены* — стеналарны агартып алу; 2. *разг.* бераз сөт салып җибәрү; әзрәк каймак салып җибәрү; азрак катык кату.

**ПОДБЕ'ЛКА** *ж.*— к. подбелить.

**ПОДБЕ'ЛЬЩИК** *м. спец.*— агартучы (эшче).

**ПОДБЕРЕ'ЖНИК** *м. бот.*— яр буе үсемлеге (дымлы урында үсә торган үлән яки куак).

**ПОДБЕРЕ'ЖНЫЙ** *обл.*— яр кырыендагы, яр буена урнашкан; *подбережный посёлок* — яр буена урнашкан авыл.

**ПОДБЕРЕ'ЗНИК, ПОДБЕРЁЗОВИК** *м.*— каен гөмбәсе.

**ПОДБИВА'ТЬ** *несов.*— к. подбить.

**ПОДБИВА'ТЬСЯ** *несов. простореч.*— к. подбиться.

**ПОДБИ'ВКА** *ж.*— 1. к. подбить 1, 2, 4, 5, 6; 2. *обл.* эчлек (кием эчлеге); *сатиновая подбивка* — сатин эчлек.

**ПОДБИРА'ТЬ** *несов.*— к. подобрать.

**ПОДБИРА'ТЬСЯ** *несов.*— к. подобраться.

**ПОДБИ'ТЬ** *сов.*— 1. аслык салу, олтан салу, төп салу, төпләү; *подбить валенки* — киез итекләргә олтан салу; 2. *портн.* эчләү, эчлек кую; *подбить шёлком* — ефәк эчлек кую; 3. *безл.* агызып китерү, агызып китереп (ташлап) калдыру; *лодку подбило под мост* — көймәне күпер астына агызып китереп ташлаган; 4. бәреп аудару; *подбить кеглю* — кегльне бәреп аудару; 5. бәреп имгәтү, сугып имгәтү, бәреп кара яндыру; *подбить глаз* — күзне сугып кара яндыру; *подбить ногу собаке* — этнең аягын бәреп

имгәтү; 6. атып яралау, бәреп тәшерү, атып төшерү; *подбить ястреба* — карчыганы атып төшерү; *подбить самолёт* — самолётны атып төшерү; 7. *разг.* котырту; ризалату, күндерү; *бьюсь об заклад, что он подбил Карла Ивановича приехать сегодня* (*Григорович*) — билләһи дип әйтәм, ул Карл Ивановичны бүген килергә күндергәндер. ◇**Седло подбило спину лошади** — ияр атның аркасын кырган.

**ПОДБИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — үз ягына аудару, ышанычын казану; *подбился я к дочери шорника и с нею отца обокрал* (*Некрасов*) — шорникның кызын үз ягыма аудардым да, аның белән бергә атасының әйберләрен урладым.

**ПОДБЛЮ'ДНИК** *м. устар.* — тәлинкә аслыгы, тирән тәлинкә астына куела торган сай тәлинкә.


**ПОДУ'МАТЬ** *сов.*—1. уйлау, уйлап карау, бераз уйлый төшү; 2. уйланып тору (берникадәр вакыт). ◇ **Подумаешь** *разг.*— исең киткән икән! харап инде! **Подумайте (подумать) только** *разг.*— уйлап кына кара; *подумать только, как много он пережил* — уйлап кына кара, күпме нәрсә кичергән ул башыннан. **И не подумаю** — уйлап та карамам (исем дә китмәс). **И подумать не смей** — уйлама да, башына да китермә.

**ПОДУ'МАТЬСЯ** *безл. сов. разг.*— уйга килү, фикергә килү, уйлау; *а мне подумалось, что ты уже не придёшь* — ә мин син инде килмәссең дип уйлаган идем.

**ПОДУ'МЫВАТЬ** *несов. разг.*— уйлап карау, уйлаштыргалау, (берәр нәрсә эшләргә) ният итү.

**ПОДУ'МЫВАТЬСЯ** *несов. разг.*— к. подуматься.

**ПОДУРА'ЧИТЬ** *сов. разг.*— шаяртып алу, котыртып алу.

**ПОДУРА'ЧИТЬСЯ** *сов. разг.*—1. шаярып алу, юләрләнеп алу; 2. көлү (берәр кешедән).

**ПОДУ'РИВАТЬ** *несов. разг.*— юләрләнгәләү, вакыт-вакыт акылсызлык күрсәтү, җеңләнгәләү, тиләләнгәләү.

**ПОДУРИ'ТЬ** *сов. разг.*— к. подурачиться 1.

**ПОДУРНЕ'ТЬ** *сов.*— ямьсезләнеп китү, ямьсезләнә төшү.

**ПОДУСА'ДЕБНЫЙ** *спец.*— йорт янындагы; *подусадебный участок* — йорт янындагы участок.

**ПОДУ'СНИКИ** *м.*— мыек очлары.

**ПОДУСТИ'ТЕЛЬ** *м. устар.*— коткы салучы, котыртучы.

**ПОДУСТИ'ТЬ** *сов. устар.*—котырту, коткы салу.

**ПОДУ'СЬКАТЬ** *сов. простореч.*—1. өстерү (этне); 2. *фам.* котырту (кешене).

**ПОДУ'СЬКИВАТЬ** *несов. простореч.*— к. подуськать.

**ПОДУ'СЬКИВАТЬСЯ** *несов. страд. простореч.*— котыртылу; өстерелү.

**ПОДУ'ТЬ** *сов.*—1. исү, җил исеп китү, җил исеп кую; 2. өрү, өреп җибәрү, өреп кую (мәсәлән, кайнар чәйгә).

**ПОДУТЮ'ЖИВАТЬ** *несов. разг.*— к. подутюжить.

**ПОДУТЮ'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— үтүкләп алыну, үтүкләп җибәрелү.

**ПОДУТЮ'ЖИТЬ** *сов. разг.*— үтүкләп алу, үтүкләп җибәрү, бераз үтүкли төшү.

**ПОДУТЮ'ЖНИК** *м. спец.*— үтүк астына куела торган әйбер, үтүк аслыгы.

**ПОДУЧА'ТЬ** *несов. простореч.*— к. подучить 3.

**ПОДУЧА'ТЬСЯ** *несов. страд. простореч.*— котыртылу, өйрәтелү (начарлыкка).

**ПОДУ'ЧИВАТЬ** *несов.*— к. подучить.

**ПОДУ'ЧИВАТЬСЯ** *несов.*—1. к. подучиться; 2. *страд.* өйрәтелү, тагы да бераз өйрәтелү.

**ПОДУЧИ'ТЬ** *сов.*— 1. *разг.* бераз өйрәтеп алу, тагы да бераз өйрәтү; 2. *разг.* (*заучить получше*) яхшырак өйрәнү, яхшырак үзләштерү; 3. котырту, өйрәтү (начарлыкка).

**ПОДУЧИ'ТЬСЯ** *сов.*— бераз өйрәнеп алу.

**ПОДУ'ШЕЧКА** *ж.*— кулчек (кечкенә генә мендәр).

**ПОДУ'ШИНА** *ж. обл. истор.*— җан башыннан алынган салым, имана.

**ПОДУШИ'ТЬ** I *сов.*—1. *разг.* буып үтерү, буып үтереп бетерү; 2. буып тору.

**ПОДУШИ'ТЬ** II *сов.*— бераз ислемай сөртү, бераз ислемай бөркү.

**ПОДУШИ'ТЬСЯ** *сов.*— бераз ислемай сөртенү.

**ПОДУ'ШКА** *ж.*— мендәр.

**ПОДУ'ШНЫЙ** *офиц. истор.* — җан башыннан алына торган; җан башына салына торган; *подушный налог* — җан башыннан алына торган салым.

**ПОДУЩА'ТЬ** *несов. устар.*— к. подустить.

**ПОДФА'РНИК** *м. тех.*— подфарник (автомобильнең алгы канатындагы ярдәмче кечкенә фонарь).

**ПОДХА'ЖИВАТЬ** *несов. разг. фам.*— ялагайланып берәр үтенеч белән мөрәҗәгать итү, берәр үтенеч белән мөрәҗәгать итеп туйдырып бетерү, йодәтеп бетерү.

**ПОДХАЛИ'М** *м. разг. презрит.*— подхалим, ялагай, куштан, алдакчы.

**ПОДХАЛИМА'Ж** *м. мн.* нет, *нов. разг. фам. презрит.*— подхалимлык, ялагайлык.

**ПОДХАЛИ'МИСТЫЙ** *простореч. презрит.*— подхалимрак, ялагайрак, икейөзлерәк (кеше).

**ПОДХАЛИ'МНИЧАТЬ** *несов. разг. презрит.*— подхалимлык итү, ялагайлану, икейөзле булып йөрү.

**ПОДХАЛИ'МСКИЙ** *разг. презрит.*— подхалимнарча...; *подхалимское поведение* — үзеңне подхалимнарча тоту.

**ПОДХАЛИ'МСТВО** *ср. мн.* нет, *разг. презрит.*— подхалимлык, ялагайлык.

**ПОДХАЛИ'МСТВОВАТЬ** *несов. разг. презрит.*— к. подхалимничать.

**ПОДХАЛЮ'ЗА** *м.* и *ж.*, **ПОДХАЛЮ'ЗНИК** *м. простореч. презрит.*— к. подхалим.

**ПОДХАЛЮ'ЗНИЧАТЬ** *несов. простореч. презрит.*— к. подхалимничать.

**ПОДХВА'Т** *м.*—1. к. подхватить 1, 2; 2. *порт. устар.* (*вырез для рукавов*) җиң уемы.

**ПОДХВАТА'ТЬ** *сов. простореч.*— эләктереп җыеп алу.

**ПОДХВАТИ'ТЬ** *сов.*—1. астыннан тотып күтәрү; 2. (хәрәкәттәге әйберне җиргә төшеп җиткәндә) тотып алу, эләктереп алу; 3. *разг. фам.* үзең белән алу; 4. *перен. разг. фам.* алу, эләктерү, эләктереп алу; *подхватить болезнь* — авыру эләктерү; *где ты подхватил такого товара?* (Даль) — кайдан эләктердең син мондый товарны? 5. *перен. простореч.* элеп алу, эләктереп алу; *у кого он подхватил эту мысль?*— кемнән эләктереп алган ул бу фикерне? 6. кушылып җырлый башлау, ялгап алып китү (җырны, сүзне); 7. күтәреп алу, хуплап каршы алу, хуплап кабул итү, кушылу, яклау; *подхватить инициативу масс* — массаларның инициативасын күтәреп алу, массаларның инициативасын яклау; 8. бик тиз кузгалып китү, кинәт кузгалу; *лошади подхватили от крыльца и быстро вынесли нас за ворота* — атлар баскыч төбеннән кинәт кузгалдылар да безне бик тиз генә капкадан алып чыгып киттеләр; 9. *разг.* астан чалып бәйләү, (бәйли торган җепне) астан үткәрү; 10. *порт.* астан тегеп кую.

**ПОДХВАТИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— астан (очыннан) эләктереп алу, астыннан тотыну; *он подхватился за верёвку* — ул бауның очына тотынды (очыннан эләктереп алды).

**ПОДХВА'ТЫВАТЬ** I *несов.*— к. подхватить.

**ПОДХВА'ТЫВАТЬ** II *несов. простореч.*— к. подхватать.

**ПОДХВА'ТЫВАТЬСЯ** *несов. разг.*— подхватиться.

**ПОДХЛЕСТНУ'ТЬ, ПОДХЛЕСНУ'ТЬ** *сов.*— 1. чыбыркылап алу, бераз чыбыркы белән суккалау; 2. *перен. разг. фам.* ашыктыру; *надо подхлестнуть отстающих* — артта калучыларны ашыктырырга кирәк; 3. ачуландыру, кагылу, сугу, тию; *это подхлестнуло его самолюбие* — бу аның мин-

миңлегенә тиде; 4. *обл.* астан үткәрү; *подхлестнуть верёвку под воз* — бауны йөк астыннан үткәрү.

**ПОДХЛЁСТЫВАТЬ** *несов.* — к. подхлестнуть.

**ПОДХО'Д** *м.* — 1. к. подойти 1, 2, 3, 4; 2. ...-га якын урын, ...-га якын юл, ...-га якынаю юлы, ... янындагы урын; *на подходах к станции* — станциягә якын урыннарда; 3. мөнәсәбәт, якын килү; *правильный подход к делу* — эшкә дөрес мөнәсәбәт.

**ПОДХО'ДЕЦ** *м. разг. фам. ирон.* — к. подход 3. ◇ **С подходцем** *разг. фам.* — хәйлә белән, читләтеп; *всегда говорить с подходцем* — һәрвакыт хәйлә белән сөйләү.

**ПОДХОДИ'ТЬ** *несов.* — к. подойти. ◇ **Подходить к концу** — тәмамланып килү.

**ПОДХОДЯ'ЩЕ** *нареч. простореч.* — шәп, ярыйсы; *подходяще сделано* — ярыйсы эшләнгән.

**ПОДХОДЯ'ЩИЙ** — яраклы, кулай, лаек, ярый торган, туры килә торган, уңайлы.

**ПОДХОЛА'ЖИВАТЬ** *несов. обл.* — әзрәк суыту, суыта төшү, туңдырып җибәрү; *хоть и май, а к ночи всё ещё подхолаживает* — май булса да, төнгә таба һаман да әзрәк суыта әле.

**ПОДХОМУ'ТНИК** *м. спец.* — камыт асլыгы, камыт киезе.

**ПОДХОРУ'НЖИЙ** *м. воен. дореvол.* — подхорунжий (казачий гаскәрләрдә подпоручик).

**ПОДЦА'ПАТЬ** *сов. простореч.* — к. подцапнуть.

**ПОДЦА'ПНУТЬ** *сов. простореч.* — эләктерү, чәлдерү, урлау.

**ПОДЦА'ПЫВАТЬ** *несов. простореч.* — к. подцапнуть.

**ПОДЦВЕТИ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. *разг.* буйый төшү; 2. *спец.* буяу, төс кертү.

**ПОДЦВЕ'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. подцветить.

**ПОДЦЕДИ'ТЬ** *сов. разг.* — тагы бераз сөзү, бераз саркытып алу (сыек әйберне).

**ПОДЦЕДИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — тагы да бераз сөзелү, саркытылу (сыек әйбер).

**ПОДЦЕ'ЖИВАТЬ** *несов. разг.* — к. подцедить.

**ПОДЦЕ'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — к. подцедиться.

**ПОДЦЕНЗУ'РНЫЙ** *устар.* — цензура карамындагы, цензура таләпләренә буйсынган; *подцензурная пресса* — цензура карамындагы матбугат.

**ПОДЦЕПИ'ТЬ** *сов.* — 1. *разг.* китереп эләктерү тагу; *подцепить вагон к поезду* — вагонны поездга китереп тагу; 2. астан эләктерү, эләктереп алу; 3. эләктерү, алу; *подцепить насморк* — томау эләктерү; 4. *простореч.* чәлү, урлау.

**ПОДЦЕПИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — (астан) ябышып асылыну.

**ПОДЦЕПЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. подцепить.

**ПОДЦЕПЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. *разг.* подцепиться; 2. *страд.* эләктереп куелу, эләктерелү, тагылу.

**ПОДЦЕПНО'Й** *спец.* — арттан (астан) эләктереп куелган (әйбер), тагылган (әйбер).

**ПОДЧА'Л** *м. спец.* — к. подчалок.

**ПОДЧА'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. подчалить.

**ПОДЧА'ЛИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *спец.* к. подчалиться; 2. *страд.* якын китереп (тартып) бәйләнү, бәйләп куелу (мәсәлән, бүрәнәнең көймәгә бәйләп куелуы).

**ПОДЧА'ЛИТЬ** *сов.* — 1 *спец.* эләктереп тартып китерү; *подчалить бревно к лодке багром* — бүрәнәне багор белән эләктереп көймә янына тартып китерү; 2. *спец.* килеп туктау; *подчалить к пристани* — пристань янына килеп туктау; 3. *перен. простореч. фам.* к. подцепить 3.

**ПОДЧА'ЛИТЬСЯ** *сов. спец.* — килеп туктау; *лодка подчалилась к пристани* — көймә пристаньга килеп туктады.

**ПОДЧА'ЛОК** *м. спец.* — баржа, тагылма йөк судносы.

**ПОДЧА'С** *нареч. разг.* — кайвакыт, кайчакларда.

**ПОДЧА'СОК** *м. воен.* — часовой ярдәмчесе.

**ПОДЧЕЛЮСТНО'Й** *анат.* — казналык асты ...-ы; *подчелюстные железы* — казналык асты бизләре.

**ПОДЧЕРЕПНО'Й** *анат.* — баш сөяге эчендәге.

**ПОДЧЁРКИВАТЬ** *несов.* — к. подчеркнуть.

**ПОДЧЁРКИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. астына сызылу; 2. *перен.* аерып (басым ясап) әйтелү, ассызымлап әйтелү.

**ПОДЧЁРКНУТЫЙ** — 1. астына сызылган; 2. аерылып торган, күзгә бәрелеп торган, аеруча.

**ПОДЧЕРКНУ'ТЬ** *сов.* — 1. астына сызу; *подчеркнуть в рукописи особенно важные места* — кульъязмада аеруча әһәмиятле урыннарның астына сызу; 2. *перен.* (*выделить, как особенно важное*) аерып әйтү, аеруча бүлеп әйтү, аерып алу, иң әһәмиятлесен күрсәтү, басым ясап әйтү, ассызымлап әйтү.

**ПОДЧЕРНИ'ТЬ** *сов.* — каралта төшү, бераз каралтып җибәрү, карага буяу (мәсәлән, сөрмә тарту).

**ПОДЧЕРНИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — каралтып җибәрү, каралту (үз чәчеңне, кашларыңны).

**ПОДЧЕРТИ'ТЬ** *сов.* — сызымны төзәтү; сызымга өстәү; *подчертить новую линию* — сызымга яңа сызык өстәү.

**ПОДЧЕ'РЧИВАТЬ** *несов.* — к. подчертить.

**ПОДЧЕ'РЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — өстәп сызылу, сызык өстәлү.

**ПОДЧЕСА'ТЬ** *сов. разг.* — кашып бераз ерту, кашып бераз бозу (яраны).

**ПОДЧЁСЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. подчесать.

**ПОДЧИНЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. к. подчинить; подчиниться; 2. *грам.* иярү, ияртү; *соединение предложений по способу подчинения* — җөмләләрне ияртү юлы белән бәйләү.

**ПОДЧИНЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — буйсынулы хәл, буйсынучылык, буйсынганлык, бәйлелек.

**ПОДЧИНЁННЫЙ** — 1. буйсынган, бәйле кул астындагы; 2. *грам.* иярчен (җөмлә).

**ПОДЧИНИ'ТЕЛЬНЫЙ** *грам.* — иярүле, ияртүле; *подчинительные конструкции* — ияртүле конструкцияләр.

**ПОДЧИНИ'ТЬ** *сов.* — 1. *книж. (покорить)* яулап алу; 2. буйсындыру; *подчинить закону* — законга буйсындыру; 3. *грам.* (ияртү юлы белән) буйсындыру (иярчен җөмләне баш җөмләгә буйсындыру).

**ПОДЧИНИ'ТЬСЯ** *сов.* — буйсыну, баш ию.

**ПОДЧИНЯ'ТЬ** *несов.* — к. подчинить.

**ПОДЧИНЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. подчиниться; 2. *страд.* буйсындырылу.

**ПОДЧИ'СТИТЬ** *сов.* — 1. чистартып алу, чистартып җибәрү; 2. пычракны, чүпне җыеп алу; *подчистить за маляром* — маляр калдырган пычракны, чүпне җыеп алу; 3. *спец.* (агачның корыган ботакларын, артык сабакларын) кисеп алу, кыркып алу; 4. кырып чистарту; 5. *разг. фам. неодобр.* или *шутл.* чистарту, бөтенләй алып бетерү; ашап бетерү; *воры подчистили все деньги* — караклар барлык акчаны алып бетергәннәр; *кошка всю сметану подчистила* — мәче барлык каймакны ашап бетергән.

**ПОДЧИ'СТИТЬСЯ** *сов. разг.* — бераз чистара төшү, чистарып калу.

**ПОДЧИСТУ'Ю** *нареч. простореч.* — барын да, берни калдырмыйча, тап-такыр итеп; *съели всё подчистую* — берни калдырмыйча ашап бетергәннәр.

**ПОДЧИТА'ТЬ** *сов.* — 1. *разг.* тагы да бераз уку, бераз укыштырып алу; 2. *спец.* (оригиналның текстын) кычкырып уку (корректураны тикшергәндә).

**ПОДЧИ'ТЧИК** *м. спец.* — кычкырып укучы (корр ктураны тикшергәндә).

**ПОДЧИ'ТЫВАТЬ** *несов.* — к. подчитать.

**ПОДЧИ'ТЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. тагы да бераз укылу; 2. (оригиналның тексты) кычкырып укылу (корректура тикшерелгәндә).

**ПОДЧИЩА'ТЬ** *несов.* — к. подчистить.

**ПОДЧИЩА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. *разг.* подчиститься; 2. *страд.* бераз чистартып алыну, чистартып җибәрелү.

**ПОДШВЫ'РИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. подшвырнуть.

**ПОДШВЫ'РИВАТЬСЯ** *несов. простореч. страд.* — югарыга таба ыргытылу.

**ПОДШВЫРНУ'ТЬ** *сов. простореч.* — югарыга таба ыргыту.

**ПОДШЕ'ЕК** *м. простореч. спец.* — муен асты.

**ПОДШЕ'ЙНЫЙ** — муенга бәйләнгән, муенга эленгән; *подшейный бубенчик* — муенга бәйләнгән шөлдер.

**ПОДШЕПНУ'ТЬ** *сов. разг.* — пышылдап кына әйтеп кую.

**ПОДШЁРСТОК** *м. спец.* — йон-мамык, терлек мамыгы (кәҗә, дөя һ. б. мамыгы).

**ПОДШЕФЕ'** — к. подшофе.

**ПОДШЕ'ФНИК** *м.* — подшефник (шефка алынган кеше яки учреждение).

**ПОДШЕ'ФНЫЙ** — шефка алынган, ... карамагына алынган.

**ПОДШИБА'ТЬ** *несов. простореч.* — к. подшибить.

**ПОДШИБА'ТЬСЯ** *несов. страд. простореч.* — бәреп төшерелү, сугып имгәтелү.

**ПОДШИБИ'ТЬ** *сов. разг.* — сугып имгәтү, бәреп төшерү, сугып күгәртү, сугып егу.

**ПОДШИВА'ЛЬЩИК** *м. спец.* — ас салучы, аслык тегүче.

**ПОДШИВА'ТЬ** *несов.* — к. подшить.

**ПОДШИВА'ТЬСЯ** *несов.* — к. подшиться.

**ПОДШИ'ВКА** *ж.* — 1. к. подшить; 2. *спец.* тегеп куелган газеталар, документлар төргәге.

**ПОДШИВНО'Й** — астан тегеп куелган, астан тегелгән.

**ПОДШИ'ПНИК** *м. тех.* — подшипник.

**ПОДШИ'ПНИКОВЫЙ** *тех.* — подшипник ...-ы; подшипник өчен булган; *подшипниковые сплавы* — подшипник өчен булган эретмәләр.

**ПОДШИ'ТЬ** *сов.* — 1. *портн.* астан тегеп кую, эчтән тегеп кую; 2. каю, читен бөгеп тегеп кую (мәсәлән, яулыкның); 3. *сапож.* аслык салу, олтан салу; 4. *плотн.* астан такталар кагып (сугып) кую; 5. *канц.* теркәп кую, тегеп кую; *подшить документы* — документларны теркәп кую. ◇ **Подшить к делу** — 1. делога (папкага) тегеп кую; 2. *перен. разг.* тик яткыру, әһәмият бирмәү (берәр эшкә).

**ПОДШИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — астан тегеп куелу, эчтән тегеп куелу.

**ПОДШКИ'ПЕР** *м. мор.* — шкипер ярдәмчесе.

**ПОДШКИ'ПЕРСКИЙ** *мор.* — шкипер ярдәмчесе...-ы; *подшкиперская каюта* — шкипер ярдәмчесе каютасы.

**ПОДШЛЕ'МНИК** *м.* — подшлемник (шлем астыннан кия торган баш киеме).

**ПОДШОФЕ'** *устар. разг. шутл.* — бераз эчкән, эчеп кәефе килгән, кызмача.

**ПОДШПИ'ЛИВАТЬ** *несов. разг.* — к. подшпилить.

**ПОДШПИ'ЛИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — астан булавка белән кадап куелу.

**ПОДШПИ'ЛИТЬ** *сов. разг.* — астан булавка белән кадап кую.

**ПОДШТА'ННИКИ** *ед.* нет, *простореч.* — ыштан.

**ПОДШТО'ПАТЬ** *сов.* — тупчып ямау, штопать итеп кую.

**ПОДШТО'ПЫВАТЬ** *несов.* — к. подштопать.

**ПОДШТО'ПЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — тупчып ямалу, штопать итеп куелу.

**ПОДШТУКАТУ'РИВАТЬ** *несов.* — к. подштукатурить.

**ПОДШТУКАТУ'РИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — әзрәк штукатурлану, стенага бераз штукатура сылану.

**ПОДШТУКАТУ'РИТЬ** *сов.* — штукатурасын төзәтү, штукатурлап алу.

**ПОДШТУ'РМАН** *м. мор.* — штурман ярдәмчесе.

**ПОДШУТИ'ТЬ** *сов.* — шаяртып алу, көлү (берәр кешедән).

**ПОДШУ'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. подшутить.

**ПОДЩЕЛА'ЧИВАТЬ** *несов. хим.*— бераз селте өстәү.

**ПОДЩЁЛКИВАТЬ** *несов.*— к. подщелкнуть.

**ПОДЩЕЛКНУ'ТЬ** *сов.*— шартлатып кую; *подщелкнуть языком* — телне шартлатып кую.

**ПОДЩЕПА'ТЬ** *сов. разг.*— бераз чыра телеп алу, бераз чыра телеп кую.

**ПОДЩИПА'ТЬ** *сов. разг.*— йолкып ашап бетерү; *корова всю траву подщипала* — сыер бөтен үләнне йолкып ашап бетергән.

**ПОДЩИ'ПЫВАТЬ** *несов. разг.*— к. подщипать.

**ПОДЩИ'ПЫВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— йолкып ашап бетерелү.

**ПОДЪЕДА'ТЬ** *несов. разг.*— подъесть.

**ПОДЪЕДА'ТЬСЯ** *несов. страд разг.*— 1. астан ашалу; 2. ашап бетерелү.

**ПОДЪЕ'ЗД** *м.*—1. к. подъехать; 2. (өйнең) урам як ишеге; 3. (берәр нәрсә янына) килү юлы; 4. *(помост для въезда)* күпер (мәсәлән, машиналар керү өчен гараж ишеге төбендә ясалган күпер — такта мәйданчык).

**ПОДЪЕ'ЗДИТЬ** *сов. спорт. воен.*— (жигүгә, атланып йөрүгә) ат өйрәтү.

**ПОДЪЕЗДНО'Й** *спец. ж.-д.*— олы юлга чыга торган; *подъездные пути* — олы юлга чыга торган юллар.

**ПОДЪЕ'ЗДЧИК** *м. спорт. воен.*— (жигүгә, атланып йөрүгә) ат өйрәтүче.

**ПОДЪЕЗЖА'ТЬ** *несов.*— к. подъехать.

**ПОДЪЁМ** *м.*—1. күтәрү, күтәрелү; *подъём тяжестей* — авырлыкларны күтәрү; *подъём воды в реке* — елгада суның күтәрелүе; 2. тауга менү юлы; 3. аяк йөзе; *сапоги жмут в подъёме* — итекләр аяк йөзен кыса; 4. итек тамагы; *сапоги с низким подъёмом* — тар тамаклы итек; 5. көчле күтәрелеш, үсеш; *подъём науки* — фәннең көчле үсеше; 6. дәрт, күтәренкелек, күтәренке рух; *играть пьесу с подъёмом* — пьесаны күтәренкелек белән уйнау; 7. *устар.* юлга чыгу; *получить деньги на подъём* — юлга чыгу өчен акча алу; 8. *тех.* күтәрү механизмы. ◇ **Лёгок на подъём** *разг.*— елгыр, житез хәрәкәтле, жиңел сөякле. **Тяжёл на подъём** *разг.*— салмак кеше, әкертен кеше, авыр сөякле. **В подъём** *разг.*— көче житә, хәленнән килә; *это ему не в подъём* — моңа аның көче житми, бу аның хәленнән килми.

**ПОДЪЁМИСТЫЙ** *простореч.*— калку йөзле (аяк).

**ПОДЪЁМНИК** *м. тех.*— күтәргеч (авырлыклар күтәрү механизмы).

**ПОДЪЁМНЫЙ** —1. күтәрү...-ы; *подъёмный кран* — күтәрү краны; *подъёмная машина* — күтәрү машинасы; 2. күтәрелмә, күтәрелә торган, күтәреп ачыла торган; *подъёмный мост* — күтәрелмә күпер; 3. күтәренке, дәртле; *подъёмное на троение* — күтәренке күңел; 4. күчеп китү өчен бирелгән; юлга чыгу өчен бирелгән; *подъёмные деньги* — күчеп китү өчен бирелгән акча.

**ПОДЪЁМЩИК** *м. спец.*— күтәртүче (күтәрү эшләрендәге эшче).

**ПОДЪЕСАУ'Л** *м. доревол.*— подъесаул (казачий гаскәрләрдә офицер чины).

**ПОДЪЕ'СТЬ** *сов. разг.*—1. *(поесть снизу)* астан ашау, астан кимерү; 2. *простореч.* ашап бетерү; *дети всю картошку подъели* — балалар барлык бәрәңгене ашап бетергәннәр; 3. *простореч.* ашап алу, тамак ялгап алу.

**ПОДЪЕ'ХАТЬ** *сов.*—1. килеп житү (атта, машинада һ. б.); 2. ... янына килеп туктау; *автомобиль подъехал к вокзалу* — автомобиль вокзал янына килеп туктады; 3. *простореч. фам.* килеп чыгу (атта, машинада); *я к тебе подъеду вечером* — мин сиңа кич белән килеп чыгармын; 4. *перен. разг. фам.* якын килү, кылын тартып карау; *с которой бы стороны к нему подъехать?* — ничек кенә аның кылын тартып карыйсы икән?

**ПОДЪЯ'ЗОК** *м.*— бәртәс, опты (балыгы).

**ПОДЪЯЗЫ'ЧНЫЙ** *анат.* и *спец.*— тел асты...-ы; тел астындагы; *подъязычный нерв* — тел асты нервы.

**ПОДЪЯРЕ'МНЫЙ, ПОДЪЯРЁМНЫЙ** *книж. ритор.*— коллыкка төшерелгән, кол ителгән.

**ПОДЪЯ'ТЬ** *сов. книж. ритор. устар.*— к. поднять.

**ПОДЪЯ'ТЬСЯ** *сов. книж. ритор. устар.*— к. подняться.

**ПОДЫГРА'ТЬ** *сов. разг.*— (җырга яки инструментта уйнаучыга) кушылып уйнау.

**ПОДЫГРА'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.*— к. подыгрываться.

**ПОДЫГРЫВА'ТЬ** *несов. разг.*— к. подыграть.

**ПОДЫ'ГРЫВАТЬСЯ** *несов. разг. фам.*— юкә чөй кагу, салам кыстыру, юри ошаткан булу.

**ПОДЫМА'ТЬ** *несов. простореч.*— к. поднимать.

**ПОДЫМА'ТЬСЯ** *несов. простореч.*— к. подниматься.

**ПОДЫМИ'ТЬ** *сов. разг.*—1. төтен чыгарып алу, бераз төтен чыгару; 2. *перен. разг. шутл.*— тәмәке тартып алу.

**ПОДЫМИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— к. подымить 1.

**ПОДЫ'МНЫЙ** *истор.*— өй башыннан алына торган (җыем, салым).

**ПОДЫСКА'ТЬ** *сов.*— эзләп табу.

**ПОДЫ'СКИВАТЬ** *несов.*— к. подыскать.

**ПОДЫ'СКИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— эзләп табылу.

**ПОДЫТО'ЖИВАТЬ** *несов.*— к. подытожить.

**ПОДЫТО'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— йомгак ясалу, нәтиҗә чыгарылу, йомгаклану; суммасы исәпләп чыгарылу.

**ПОДЫТО'ЖИТЬ** *сов.*— йомгак ясау, нәтиҗә чыгару, йомгаклау; суммасын исәпләп чыгару.

**ПОДЫХА'ТЬ** *несов.*—1. к. подохнуть; 2. *перен. простореч. фам.* үлә язу, хәл китү, көчкә генә үткәрү, авыр кичерү; *я подыхал от жары* — эсседән үлә яздым.

**ПОДЫША'ТЬ** *сов.* — сулау, сулыш алу, бераз тын алу.

**ПОДЬЯ'ЧЕСКИЙ** *устар.* — подьячий...-ы; *подьяческий ответ* — подьячий җавабы.

**ПОДЬЯ'ЧИЙ** *м. истор.* — подьячий (борынгы Русьта дьяк ярдәмчесе, приказ канцеляриясендә писарь һәм эш башкаручы).

**ПОДЮЖЕ'ТЬ** *сов. обл.* — көчлерәк булып китү, тазарып китү, көрәеп китү.

**ПОЕГОЗИ'ТЬ** *сов. разг.* — (бераз вакыт) кайнашып алу, кыбырсыкланып алу.

**ПОЕДА'ТЬ** *несов.* — к. поесть 2, 3.

**ПОЕДА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — ашап бетерелү.

**ПОЕДИ'НОК** *м.* — 1. бергә бер чыгып сугышу, атышу, дуэль, бергә бер чыгып көрәшү; 2. *перен. книж.* бәхәс, диспут; *словесный поединок* — сүз бәхәсе (сүз көрәштерү).

**ПОЕДО'М** и *обл.* **ПО'ЕДОМ** *нареч. простореч.*: **есть поедом** — бертуктаусыз орышу, мәсхәрәләү.

**ПОЁЖИВАТЬСЯ** *несов.* — к. поёжиться.

**ПОЁЖИТЬСЯ** *сов.* — бөрешү, бөрешеп тору, куырылу, куырылып тору (мәсәлән, суыктан).

**ПО'ЕЗД** *м.* — 1. поезд; 2. бер-бер артлы бара торган җигүле арбалар, чаналар.

**ПОЕ'ЗДИТЬ** *сов.* — (атка, машинага утырып) йөреп кайту, йөреп чыгу, сәяхәт кылу, гизү; *поездить по свету* — дөнья гизү, күп сәяхәт кылу.

**ПОЕ'ЗДКА** *ж.* — юл йөрү, кыска вакытлы сәфәр, йөреп кайту, барып кайту (атта, машинада).

**ПОЕЗДНО'Й** — поезд...-ы; поезддагы; *поездная бригада* — поезд бригадасы; *поездное радио* — поезддагы радио.

**ПОЕЗЖА'НИН** *м.*, **ПОЕЗЖА'НКА** *ж. устар. обл.* — арчи (кияүгә чыккан кызны кияү йортына озата баручы).

**ПОЕЛИ'КУ** *союз, устар.* — чөнки.

**ПОЕЛО'ЗИТЬ** *сов.* — бераз үрмәләп йөрү, бераз шуышып йөрү.

**ПОЁМ** *м. обл.* — к. пойма.

**ПОЁМНЫЙ** *обл.* — су баса торган, язгы ташкын вакытында су астында кала торган (болыннар, урманнар).

**ПОЁНЫЙ** *спец.* — сөт имеп үскән, сөт имеп тәрбияләнгән (мәсәлән, бозау).

**ПОЁРЗАТЬ** *сов. разг.* — (бераз вакыт) кыбырсык анып тору, боргаланып тору.

**ПОЕРШИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — кирләнеп тору, кәҗәләнеп алу.

**ПОЕ'СТЬ** *сов.* — 1. бераз ашап алу; 2. ашап бетерү; 3. кимереп (ашап) бозып бетерү.

**ПОЕ'ХАТЬ** *сов.* — 1. (берәр нәрсәгә утырып) китеп бару, китү; 2. *перен. разг. фам.* (берәр мәгънәсез эшкә) тотыну; *вот болтун: как поехал, теперь не остановишь* — менә лыгырдык, тотынды бит, инде туктата да алмассың.

**ПОЖА'ДНИЧАТЬ** *сов. разг.* — саранланып тору, саранлык күрсәтеп алу.

**ПОЖАЛЕ'ТЬ** *сов.* — к. жалеть.

**ПОЖА'ЛИТЬ** *сов. разг.* — (күпләрне) чагып чыгу, чагып бетерү.

**ПОЖА'ЛИТЬСЯ** *сов. простореч. обл.* — к. жаловаться.

**ПОЖА'ЛОВАТЬ** *сов. устар.* — 1. бүләк итү, яхшылык күрсәтү, яхшылык эшләү; 2. килү. ◇ **Пожалуйте** — рәхим итегез, хуш киләсез.

**ПОЖА'ЛОВАТЬСЯ** *сов.* — 1. канәгатьсезлек белдерү, зарлану; 2. жалоба бирү; 3. әләкләү, чагу.

**ПОЖА'ЛУЙ** — 1. ахрысы, бугай, ихтимал, булса кирәк; 2. мөгаен; *я, пожалуй, приду* — мин, мөгаен, килермен. ◇ **По мне пожалуй** *разг.* — килешәм, каршы килмим, мин риза.

**ПОЖА'ЛУЙСТА** — 1. ...-чы, рәхим итеп ...-чы; *дайте мне, пожалуйста, воды* — миңа су бирегезче; 2. рәхим итегез; *можете передать мне нож? — Пожалуйста!* — миңа пычак бирә алмассызмы? — Рәхим итегез! 3. зинһар; *пожалуйста не шумите* — зинһар шауламагыз. ◇ **Скажи(те) пожалуйста** *разг. фам.* — әйтегезче зинһар, бу ни эш инде, бу ни дигән сүз бу; *ну, скажите пожалуйста: ну, не совестно ли вам?* (Гоголь) — әйтегезче зинһар: я, оят түгелме инде сезгә?

**ПОЖА'Р** *м.* — 1. янгын, ут-күз, пожар; 2. көчле хәрәкәт (берәр иҗтимагый хәрәкәтнең көчле үсеше, көрәш, сугыш, революция). ◇ **Как на пожар (бежать)** *разг.* — ут чыкканмыни (шул кадәр йөгерә). ◇ **Не на пожар** *разг. фам.* — ут чыкмаган әле (өлгерерсең мәгънәсендә).

**ПОЖА'РИТЬ** *сов.* — 1. кыздырып алу; 2. *разг.* — кыздырып бетерү; *пожарить все котлеты* — барлык котлетларны кыздырып бетерү.

**ПОЖА'РИТЬСЯ** *сов.* — 1. кызу, куырылу; *мясо достаточно пожарилось* — ит җитәрлек кызган; 2. *перен. разг.* кызыну; *пожариться на солнце* — кояшта кызыну.

**ПОЖА'РИЩЕ** I *м. разг.* — зур янгын; бик зур пожар.

**ПОЖА'РИЩЕ** II *ср.* — янгын урыны, янгыннан калган урын, янгын хәрабәсе.

**ПОЖА'РНИК** *м.* — пожарник, янгын сүндерүче.

**ПОЖА'РНЫЙ** — 1. янгын...-ы; *пожарный сигнал* — янгын сигналы; 2. янгын сүндерү...-ы; *пожарный насос* — янгын сүндерү насосы; 3. *перен. разг. фам. шутл.* бик ашыгыч.

**ПОЖА'ТЬ** I *сов.* — 1. кысу, бераз кысып алу; 2. кысу, кысып чыгару, сыгып чыгару. ◇ **Пожать плечами** — (гаҗәпләнеп) иңбашларын җыеру (җыерып кую).

**ПОЖА'ТЬ** II *сов.* — 1. уру, урып бетерү; *что посеешь, то и пожнёшь* — ни чәчсәң, шуны урырсың; 2. *книж.* казану, хезмәтләре нәтиҗәсендә ирешү; *пожать славу* — дан казану; 3. әзрәк урып алу, бераз уру.

**ПОЖА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. кысылу, бөрешү (мәсәлән, салкыннан); 2. *простореч.* бераз саранлану, бераз саранланып тору; *пожался, но дал всё-таки в долг* — бераз саранланып торса да, бурычка бирде.

**ПОЖДА'ТЬ** *сов. разг.* — әзрәк көтеп тору, бераз көтеп тору.

**ПОЖЕВА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. (бераз вакыт) чәйнәп тору, (бераз вакыт) чәйнәү; 2. чәйнәп карау; *он пожевал сливу и выплюнул* — ул кара җимешне чәйнәп карады да төкереп ташлады.

**ПОЖЁВЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. пожевать 1.

**ПОЖЕЛА'НИЕ** *ср. книж.* — теләк; таләп, сорау, тәкъдим.

**ПОЖЕЛА'ТЬ** *сов.* — к. желать.

**ПОЖЕЛТЕ'ЛЫЙ** — саргайган, сары.

**ПОЖЕЛТЕ'ТЬ** *сов.* — саргаю, саргаеп китү, саргаеп бетү.

**ПОЖЕЛТИ'ТЬ** *сов. разг.* — саргайту, саргайта төшү, саргайтып җибәрү, бераз сарыга буяу.

**ПОЖЕМА'НИТЬСЯ** *сов. разг.* — бераз кыстатып алу, бераз кыстатып тору, бераз назланып алу, бераз кыланчыкланып тору, кыланып тору.

**ПОЖЕНИ'ТЬ** *сов. разг.* — к. женить.

**ПОЖЕНИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — өйләнешү.

**ПОЖЕ'РТВОВАНИЕ** *ср.* — 1. к. пожертвовать; 2. ярдәм (берәр кешегә яки учреждениегә күрсәтелгән ярдәм).

**ПОЖЕ'РТВОВАТЬ** *сов.* — к. жертвовать.

**ПОЖЕТО'ННЫЙ** — жетон буенча...-ы; *пожетонное вознаграждение за участие в работе комиссии* — комиссиядә эшләве өчен жетон буенча түләү.

**ПОЖЕ'ЧЬ** *сов.* — 1. яндырып бетерү; 2. яндырып алу.

**ПОЖИ'ВА** *ж. мн.* нет, *разг.* — файда, табыш.

**ПОЖИВА'ТЬ** *несов. разг.* — яшәү, тору, көн күрү.

**ПОЖИВИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — табыш итү, файда итү.

**ПОЖИГА'ТЬ** *несов.* — к. пожечь.

**ПОЖИГА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — яндырып бетерелү.

**ПОЖИДЕ'ТЬ** *сов. разг.* — сыеклана төшү.

**ПОЖИ'ЗНЕННЫЙ** — гомерлек, бөтен гомере буена тартыла торган; *пожизненная пенсия* — гомерлек пенсия.

**ПОЖИЛО'Е** *ср. мн.* нет, *разг. устар.* — 1. (өй хезмәтчесенә түләнә торган) хезмәт хакы; 2. торак бинасы өчен түләү.

**ПОЖИЛО'Й** — олы яшьтәге, картая башлаган (кеше).

**ПОЖИМА'ТЬ** *несов.* — 1. к. пожать I в 1 знач.; 2. кысып-кысып карау, басып-басып карау.

**ПОЖИМА'ТЬСЯ** *несов.* — к. пожаться 1.

**ПОЖИНА'ТЬ** *несов.* — к. пожать II в 1 знач.

**ПОЖИ'НКИ** *ед.* нет, *обл.* — урак бетү; урак бетү бәйрәме, уңыш бәйрәме.

**ПОЖИРА'ТЬ** *несов.* — к. пожрать. ◇ **Пожирать глазами** — күзе белән йоту, күзе белән ашардай булып карау.

**ПОЖИРЕ'ТЬ** *сов. разг.* — симереп китү.

**ПОЖИРНЕ'ТЬ** *сов. разг.* — к. пожиреть.

**ПОЖИ'ТКИ** *м. разг.* — өй кирәк-яраклары, вак-төяк мөлкәт.

**ПОЖИ'ТЬ** *сов.* — 1. тору, яшәү; исән булу; *поживём, увидим* — исән булсак, күрербез; 2. *разг.* әйбәт кенә яшәп алу, мул торып алу, яшәп калу.

**ПО'ЖНИВНЫЙ** *обл. с.-х.* — иген урып алынган кырга чәчелгән; *пожнивные культуры* — иген урып алынган кырга чәчелгән культуралар.

**ПО'ЖНИВО** *ср. обл. с.-х.* — к. жнивьё 1.

**ПО'ЖНЯ** *ж. с.-х.* — 1. к. пожниво; 2. *обл.* болын.

**ПОЖО'Г** *м.*, **ПОЖО'ГА** *ж. обл.* — яның, урманда янган урын.

**ПОЖО'ЛКНУТЬ** *сов. обл.* — к. пожелтеть.

**ПОЖРА'ТЬ** *сов. разг.* — комсызланып ашап бетерү; тыгыну, кабаланып ашау; 2. *перен. редко* юкка чыгару, һәлак итү, бетерү.

**ПОЖУИ'РОВАТЬ** *сов. устар.* — кәеф-сафада үткәрү, кәеф-сафа белән яшәү, типтереп яшәү.

**ПОЖУРИ'ТЬ** *сов.* — 1. *разг.* к. журить; 2. бераз шелтәләп алу, (берникадәр вакыт) тиргәп тору.

**ПОЖУ'ЧИТЬ** *сов. разг. фам.* — шелтәләп ташлау, тиргәп ташлау, (берникадәр вакыт) тиргәү.

**ПОЖУ'ХНУТЬ** *сов. обл.* и *спец.* — кибеп кату, кибеп төсен югалту, уңу.

**ПО'ЗА** *ж.* — 1. поза, гәүдә торышы; 2. *перен.* икейөзлелек, мөнафикълык, кылану. ◇ **Стать в позу** или **принять какую-нибудь позу** — нинди дә булса кыяфәткә керү (мәсәлән, мәһабәт поза алу, мәһабәт кыяфәткә керү).

**ПО-ЗА** *предлог. обл.* — артында, аръягында.

**ПОЗАБА'ВИТЬ** *сов.* — күңелен ачып алу, кәефен китерү.

**ПОЗАБА'ВИТЬСЯ** *сов.* — күңел ачып алу, кәефләнеп алу.

**ПОЗАБО'ТИТЬСЯ** *сов.* — к. заботиться.

**ПОЗАБЫВА'ТЬ** I *несов. разг.* — к. позабыть.

**ПОЗАБЫВА'ТЬ** II *сов. разг. фам.* — әкрен-әкрен оныта башлау, азлап-азлап онытып бетерү.

**ПОЗАБЫ'ТЬ** *сов. разг.* — к. забыть.

**ПОЗАБЫ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — к. забыться 1, 2, 3, 4.

**ПОЗАВИ'ДОВАТЬ** *сов.* — кызыгу, көнләшү, көнләшеп кую.

**ПОЗА'ВТРАКАТЬ** *сов.* — иртәнге ашны ашап алу.

**ПОЗАВЧЕРА'** *разг.* — өченче көн (моннан ике көн элек).

**ПОЗАВЧЕРА'ШНИЙ** *разг.* — өченче көнге.

**ПОЗАДИ'** I *предлог* — артында, арты нан; *он сидел позади меня* — ул минем артымда утыра иде; *шёл позади меня* — минем артымнан бара иде.

**ПОЗАДИ'** II *нареч.* — артта; *он сидел позади, в десятом ряду* — ул артта, унынчы рәттә утыра иде.

**ПОЗА'ДЬ** *простореч. обл.* — к. позади I и II.

**ПОЗАИ'МСТВОВАТЬ** *сов.* — 1. к. заимствовать; 2. *разг.* бурычка алу.

**ПОЗАНИМА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — шөгыльләнеп алу, эшләп алу.

**ПОЗАНЯ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — бераз шөгыльләнеп алу, бераз эшләп алу.

**ПОЗАПРО'ШЛЫЙ** *разг.* — өченче, үткән...-дан элекке; *позапрошлый год* — өченче ел, үткән елдан элекке ел.

**ПОЗА'РИТЬСЯ** *сов. простореч.* — к. зариться.

**ПОЗВА'ТЬ** *сов.* — чакыру, чакырып алу, чакырып китерү, дәшеп китерү. ◇ **Позвать в суд** *устар.* — судка бирү (бирәүне).

**ПОЗВЕНЕ'ТЬ** *сов.* — чыңлап алу, чыңлап кую, шалтырап кую.

**ПОЗВОЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — рөхсәт, рөхсәт итү, юл кую. ◇ **С позволения сказать** *ирон.* — шулай әйтергә яраса, шулай дип әйтерлек булса.

**ПОЗВОЛИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — ярый торган, рөхсәт ителерлек.

**ПОЗВО'ЛИТЬ** *сов.* — 1. рөхсәт итү, юл кую, ирек бирү; 2. *перен.* мөмкинлек бирү; *позволить ему работать* — аңа эшләргә мөмкинлек бирү. ◇ **Позволить себе** — эшли алу; эшләргә базу, кыюлык итү; *он никогда не позволит себе невежества* — ул бервакытта да тупаслык эшләмәс. ◇ **Позвольте узнать** — әйтсәгез лә, рәхим итеп әйтегез әле.

**ПОЗВОЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. позволить.

**ПОЗВОЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — рөхсәт ителү, ирек бирелү, юл куелу.

**ПОЗВОНИ'ТЬ** *сов.* — к. звонить 1, 2, 3.

**ПОЗВОНИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — к. звониться.

**ПОЗВОНО'К** *м.* — умыртка (сөяге).

**ПОЗВОНО'ЧНИК** *м.* — умырткалык, умыртка баганасы.

**ПОЗВОНО'ЧНЫЕ** *только мн. зоол.* — умырткалылар (умырткалылар семьялыгыннан булган хайваннар).

**ПОЗВОНО'ЧНЫЙ** — умырткалы; *позвоночные животные* — умырткалы хайваннар. ◇ **Позвоночный столб** — умырткалык, умыртка баганасы.

**ПОЗВУЧА'ТЬ** *сов.* — (берникадәр вакыт) шалтырап тору, чыңлап тору.

**ПОЗДНЕ'ЙШИЙ** — иң соңгы, иң соңгы вакытлардагы.

**ПОЗДНЕ'НЬКО** *нареч. разг. фам.* — бик соң, бик соңга калып.

**ПО'ЗДНИЙ** — 1. соң, соңгы; соң өлгергән, соң килгән; *поздний урожай* — соң өлгергән уңыш; *в этом году осень была поздняя* — быел көз соң килде; 3. *книж. редко* киләчәктәге, киләчәк, алда буласы; *поздние потомки* — киләчәк буыннар. ◇ **Поздней осенью** — көз ахырында.

**ПО'ЗДНО** *нареч.* — 1. соң, соңга калып, кичегеп; *поздно вернуться* — соң кайту, соңга калып кайту; 2. азагында; *поздно осенью* — көз азагында.

**ПОЗДОРО'ВАТЬСЯ** *сов.* — исәнләшү, күрешү, исәнлек-саулык сорашу.

**ПОЗДОРОВЕ'ТЬ** *сов.* — тазару, көрәю, тазарып-көрәеп китү.

**ПОЗДОРО'ВИТЬСЯ** *сов.*; **не поздоровится** *разг.* — бик әйбәт булмас, кирәген алыр, эләгер, начар булыр, рәхмәт әйтмәсләр.

**ПОЗДРАВИ'ТЕЛЬ** *м.* — котлаучы, тәбрик итүче.

**ПОЗДРАВИ'ТЕЛЬНЫЙ** — котлау...-ы; тәбрик итү...-ы; *поздравительная телеграмма* — котлау телеграммасы.

**ПОЗДРА'ВИТЬ** *сов.* — котлау, тәбрик итү.

**ПОЗДРАВЛЕ'НИЕ** *ср.* — котлау, тәбрик.

**ПОЗДРАВЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. поздравить.

**ПОЗДРАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — тәбрик ителү.

**ПОЗЕВА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. иснәп-иснәп кую; 2. *перен.* игътибарсыз утыру, әһәмият бирмичә утыру; *позевать на скучном докладе* — күңелсез докладта иснәп утыру, игътибарсыз утыру.

**ПОЗЁВЫВАТЬ** *несов. разг.* — ара-тирә иснәштергәләп кую.

**ПОЗЕЛЕНЕ'ТЬ** *сов.* — яшелләнеп китү, яшел төскә керү.

**ПОЗЕЛЕНИ'ТЬ** *сов. разг.* — яшелгә буяу, яшелләү.

**ПОЗЁМ** *м. мн.* нет, *с.-х.* — тирес (җир ашламасы).

**ПОЗЕМЕ'ЛЬНЫЙ** — җирдән файдалану...-ы; *поземельный налог* — җирдән файдалану налогы.

**ПОЗЕ'МИЦА** *ж.* — җәяүле буран.

**ПОЗЁМКА** *ж. разг.* — к. поземица.

**ПОЗЁР** *м.*, **ПОЗЁРКА** *ж. книж. неодобр.* — кыланчык кеше, икейөзле кеше, тышкы яктан гына яхшы булырга тырышучы.

**ПО'ЗЖЕ** — соңрак.

**ПОЗИМОВА'ТЬ** *сов. разг.* — кышлау, кыш үткәрү, кышлап чыгу.

**ПОЗИРОВАТЬ** *несов.* — 1. (рәсемгә төшкәндә яки художник алдында) билгеле бер кыяфәт алу, билгеле бер торышка килү; 2. *перен.* кылану.

**ПОЗИТИ'В** *м. фот.* — позитив (негативтан төшереп алынган рәсем).

**ПОЗИТИВИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.* — позитивизм (1. философиядә субъектив идеалистик юнәлешләрнең берсе; бу юнәлеш фәнгә каршы буларак, тәҗрибәне һәм фәнне субъектив сиземләүләр, күзаллаулар җыелмасы дип карый һәм аларны теоретик фикерләүгә каршы куя; 2. чынбарлыкка тәҗрибә һәм фактлар аша гына булган мөнәсәбәт).

**ПОЗИТИВИ'СТ** *м.*, **ПОЗИТИВИ'СТКА** *ж. книж.* — позитивист (позитивизмны яклаучы).

**ПОЗИТИВИ'СТСКИЙ** *книж.* — позитивизм...-ы; позитивист...-ы; *позитивистские взгляды* — позитивизм карашлары.

**ПОЗИТИ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — позитивлык; *позитивность взглядов* — карашларның позитивлыгы (уңай булуы).

**ПОЗИТИ'ВНЫЙ** *книж.* — позитив (1. реаль, фактка, тәҗрибәгә нигезләнгән; *позитивные науки* — позитив фәннәр; 2. уңай; *позитивное суждение* — позитив фикер йөртү, уңай фикер йөртү).

**ПОЗИТРО'Н** *м. физ.* — позитрон (уңай электрон).

**ПОЗИТУ'РА** *ж. спец. устар. ирон.* — позитура, гәүдә торышы, кыяфәт.

**ПОЗИЦИ'ОННЫЙ** — 1. позиция...-ы; *позиционная жизнь* — позиция тормышы; 2. позицион; *позиционная война* — позицион сугыш (башлыча, тоташ фронтның ныгытылган полосасын саклау өчен сугыш).

**ПОЗИ'ЦИЯ** *ж.* — 1. позиция, урнашкан урын; торыш, хәл; *артиллерийская позиция* — артиллерия позициясе; артиллериянең урнашкан урыны; 2. *чаще мн.* позицияләр, сугыш хәрәкәтләре районы; *на передовых позициях* — алгы позицияләрдә, сугыш хәрәкәтләре барган алгы районнарда; 3. *перен.* позиция, караш, фикер; *отстаивать свою позицию* — үз карашыңны (позицияңне) яклау.

**ПОЗЛИ'ТЬ** *сов.* — ачуландырып алу, бераз ачуын китерү.

**ПОЗЛИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — ачуланып алу, ачу чыгу, ачу килү.

**ПОЗЛО'БСТВОВАТЬ** *сов. книж.* — зәһәрләнеп алу, усаллык күрсәтеп алу, бераз зәһәрләнеп тору.

**ПОЗЛОРА'ДСТВОВАТЬ** *сов. книж.* — кеше кайгысына сөенеп тору, усал шатлану.

**ПОЗЛОСЛО'ВИТЬ** *сов. книж.* — яман телләнеп алу; төрттереп сөйләү, гайбәт сөйләү (берәү турында).

**ПОЗНА'БЛИВАТЬ** *несов. безл. разг.* — өшетеп тору, вакыт-вакыт өшетеп кую (алу).

**ПОЗНАВА'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж. филос.* — танып белеңүчелек, танып (сизеп) белеңү.

**ПОЗНАВА'ЕМЫЙ** *книж. филос.* — танып беленә торган, танып белерлек, танып беленерлек.

**ПОЗНАВА'ТЕЛЬНЫЙ** *книж. филос.* — танып белү...-ы, төшенү...-ы; *познавательный процесс* — танып белү процессы.

**ПОЗНАВА'ТЬ** *несов. книж.* — к. познать.

**ПОЗНАВА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — танып беленү, танылу, беленү. ◇ **Друзья познаются в беде** — дустым күп дип йөрерсең, эшең төшкәч белерсең; дуслык авыр минутларда беленә.

**ПОЗНАКО'МИТЬ** *сов.* — к. знакомить.

**ПОЗНАКО'МИТЬСЯ** — 1. к. знакомиться; 2. тату, белү, баштан үткәрү, кичерү.

**ПОЗНА'НИЕ** *ср. книж.* — 1. белү, танып белү, төшенеп житү, аңлап алу; *познание законов природы* — табигать законнарын танып белү; 2. *чаще мн.* белемнәр; *наши познания об Арктике* — безнең Арктика турындагы белемнәребез.

**ПОЗНА'ТЬ** *сов.* — 1. *филос.* танып белү, белү, тану; *познать природу* — табигатьне танып белү; 2. *ритор.* тату, татып карау; *познать добро и зло* — яхшылыкны һәм явызлыкны татып карау; 3. аңлау, төшенү, белү; *познать друга в несчастье* — бәхетсезлеккә төшкәндә дустыңның кем икәнен белү.

**ПОЗОЛО'ТА** *ж. мн.* нет — (бер нәрсәнең өстенә) йөгертелгән алтын.

**ПОЗОЛОТИ'ТЬ** *сов.* — 1. алтынлап алу, алтынга ману, алтын йөгертеп алу; 2. бераз вакыт алтын йөгертү. ◇ **Позолотить пилюлю** — к. пилюля.

**ПОЗОЛО'ТЧИК** *м.* — алтынга манучы, алтын йөгертүче.

**ПОЗОЛО'ЧЕННЫЙ** — алтынга манган, алтын йөгертелгән.

**ПОЗОНДИ'РОВАТЬ** *сов. книж.* — зондировать.

**ПОЗО'Р** *м. мн.* нет — 1. хурлык, оят, мәсхәрә, йөз карасы; 2. *устар.* к. позорище 1.

**ПОЗО'РИТЬ** *несов.* — хурлау, хурлыкка төшерү, оятка калдыру, яман атка калдыру, яман атлы итү, йөзенә кара ягу.

**ПОЗО'РИТЬСЯ** *несов.* — оятка калу, үз йөзенә кызыллык китерү, хурлыкка төшү, яман атка калу, яман атлы булу.

**ПОЗО'РИЩЕ** *ср.* — 1. *устар.* күренеш, тамаша; 2. хурлыклы күренеш, оят.

**ПОЗО'РНЫЙ** — хурлыклы, йөзгә кызыллык китерә торган; йөзгә кара яга торган, хур итә торган, хурлыкка төшерә торган, оятка калдыра торган. ◇ **Выставить (или пригвоздить) к позорному столбу** *ритор.* — хур итү.

**ПОЗУМЕ'НТ** *м.* — ука, укалы тасма.

**ПОЗЫ'В** *м. устар.* — 1. чакыру, өндәү; 2. судка чакыру. ◇ **Позыв на рвоту** — укшыту, косасы килү.

**ПОЗЫВА'ТЬ** *несов. разг.* — 1. *устар.* өндәү, күндерү; 2. *разг.* теләү; ...-сы килү; *позывать на еду* — ашыйсы килү. ◇ **Позывать на рвоту** — укшыту, косасы килү.

**ПОЗЫВНО'Й, ПОЗЫ'ВНЫЙ** *мор. радио* — чакыру...-ы, дикъкатьне үзенә тарту...-ы; *позывной сигнал* — чакыру сигналы.

**ПОЗЯ'БНУТЬ** *сов.* — өшү, кырау тию (үсемлекләргә).

**ПОИ'ГРАТЬ** *сов.* — уйнап алу, (бераз вакыт) уйнау.

**ПОИ'ГРЫВАТЬ** *несов. разг.* — вакыт-вакыт уйнау, уйнаштыргалау.

**ПОИЗДЕРЖА'ТЬ** *сов. разг.* — к. издержать.

**ПОИЗДЕРЖА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — акчага мохтаж булып калу.

**ПОИКА'ТЬ** *сов. разг.* — очкылык тоту.

**ПОИ'КИВАТЬ** *несов. разг.* — вакыт-вакыт очкылык тоту.

**ПОИ'ЛЕЦ** *м. нар.-поэт.*: **поилец-кормилец** — эчерүче-ашатучы.

**ПОИ'ЛКА** *ж. с.-х.* — су эчерткеч (хайваннарга һәм кошларга су эчертә торган савыт); 2. *спец.* (бөтенләй хәлсез авыруларга сыек әйберләр эчертү өчен махсус эшләнгән) чынаяк.

**ПОИМЁННО** — исеме белән атап, исемен атап.

**ПОИМЁННЫЙ** — исемнәре атап язылган.

**ПОИМЕНОВА'ТЬ** *сов. офиц.* — исемнәрен атап чыгу, атап-атап чыгу, исемнәре белән әйтеп чыгу.

**ПОИМЕ'ТЬ** *сов. разг.*: **поиметь в виду** — истә тоту.

**ПОИ'МИСТЫЙ** *охот.* — җәнлекне оста тотып ала торган.

**ПОИ'МКА** *ж. мн.* нет — к. поймать.

**ПОИМУ'ЩЕСТВЕННЫЙ** *право офиц.* — мөлкәт...-ы; *поимущественный налог* — мөлкәт налогы.

**ПОИ'МЧИВЫЙ** *охот.* — к. поимистый.

**ПОИНТЕРЕСОВА'ТЬСЯ** *сов.* — кызыксыну, беләсе килү.

**ПОИНТРИГОВА'ТЬ** *сов.* — 1. (берникадәр вакыт) интрига алып бару, астыртын хәйлә корып йөрү, кешегә баз казып йөрү; 2. бераз кызыксындыру.

**ПО'ИСК** *м.* — 1. *только мн.* эзләнүләр, тикшерүләр; 2. *воен.* (якын-тирәгә ясалган) һөҗүм, разведка.

**ПОИСКА'ТЬ** *сов.* — эзләп карау.

**ПОИСКО'ВЫЙ** *спец.* — эзләү...-ы; эзләнү...-ы; эзләп табу...-ы; разведка...-ы; *поисковые работы* — эзләү эшләре.

**ПОИ'СТИНЕ** *нареч. книж.* — дөрестән дә, чыннан да, чынлап та.

**ПОИСТРА'ТИТЬ** *сов. разг.* — к. истратить.

**ПОИСТРА'ТИТЬСЯ** *сов. разг.* — к. поиздержаться.

**ПОИ'ТЬ** *несов.* — 1. эчерү; 2. *перен. книж.* сугару; *дождь поит землю* — яңгыр җирне сугара. ◇ **Поить и кормить** *разг.* — ашатып-эчереп тору, үз тәрбиясендә тоту.

**ПО'ЙКА** *ж. мн.* нет, *обл.* — к. поить 1.

**ПО'ЙЛО** *ср.* — 1. *(питьё для скота)* куе су, он тугылаган су; 2. *обл.* терлек эчерту урыны; 3. *пренебр.* тәмсез эчемлек.

**ПО'ЙМА** *ж.* — тугай, су баса торган болын.

**ПОЙМА'ТЬ** *сов.* — тоту, тотып алу, эләктереп алу.

**ПО'ЙНТЕР** *м.* — пойнтер (шома йонлы ау эте).

**ПОЙТИ'** *сов. разг.* — 1. китеп бару, бару, китү; 2. эләгү, кабу; *окунь хорошо пойдёт на червяка* — алабуга суалчанга яхшы эләгер; 3. йөри башлау; *часы пошли* — сәгать йөри башлады; 4. ява башлау; *дождь пошёл* — яңгыр ява башлады; 5. үтү; *пойдут дни, недели за неделей* — көннәр үтәр, атна артыннан атналар үтәр; 6. дәвам итү; *игра пошла своим чередом* — уен элеккечә дәвам итте; 7. башлау; *опять пошёл спорить* — тагын сүз көрәштерә башлады; *из печи пошёл дым* — мичтән төтен чыга башлады; 8. килешү; *шляпа ей пойдёт* — эшләпә аңа килешер. ◇ **Гвоздь не пойдёт в стену** — кадак стенага кермәс. **Пойдёт в дворники** — дворник булып эшкә керер. **Пойти наравне с веком** — заманача булу. **Пошла писать губерния** *разг.* — к. губерния.

**ПОКА'** — 1. әлегә, хәзергә, әле, шул арада; *пока ничего не известно* — әле бернәрсә дә билгеле түгел; *вы посидите, а я пока схожу за водой* — сез утырып торыгыз, мин шул арада суга барып килим; 2. ...-ганда, ...-ган чакта, ...-ган арада, ...-ганчы, ...-мас борын, ...-га кадәр; *пока я спал, шёл дождь* — мин йоклаган арада яңгыр яуган. ◇ **Пока что** — әлегә. **Куй железо, пока горячо** — тимерне кызуында сук.

**ПОКА'З** *м. мн.* нет — күрсәтү, күрсәтеп бирү.

**ПОКАЗА'НИЕ** *ср. книж.* — 1. күрсәтү; 2. *офиц.* таныклык итү, җавап бирү (суд алдында).

**ПОКАЗА'ТЕЛЬ** *м. книж.* — 1. *мат.* күрсәткеч; *показатель степени* — дәрәҗә күрсәткече; 2. күрсәткеч; *качественные показатели* — сыйфат күрсәткечләре.

**ПОКАЗА'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — 1. күренекле, характерлы; *это явление весьма показательно* — бу күренеш бик характерлы; 2. күрсәтмә; *показательный судебный процесс* — күрсәтмә суд процессы; 3. үрнәк..., үрнәк булырлык; *показательный совхоз* — үрнәк булырлык совхоз.

**ПОКАЗА'ТЬ** — *сов.* — 1. күрсәтү; *он показал мне свою картину* — ул миңа үзенең картинасын күрсәтте; *показать свою храбрость* — үзенең кыюлыгыны күрсәтү; 2. аңлату, аңлатып бирү, күрсәтү, таныштыру; *я показал ему правила сложения* — мин аңа кушу кагыйдәләрен аңлаттым; *показать производство* — производство белән таныштырту; 3. (судта сорау-җавап алганда) сөйләп бирү, сөйләп күрсәтү; 4. *разг. фам.* өйрәтү, кирәген бирү, арт сабагын укыту; *я ему покажу!* — мин аның кирәген бирермен! ◇ **Показать на дверь** — куып чыгару. **Показать нос** — к. нос.

**ПОКАЗА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. күренү, булып күренү, тоелу; 2. килеп чыгу, күренеп китү; *он только показался* — ул күренеп кенә китте; 3. *простореч.* и *обл. (понравиться)* ошау.

**ПОКАЗНО'Й** — 1. үрнәк өчен эшләнгән, үрнәк өчен куелган (яхшы); 2. *(рассчитанный на эффект)* күрсәтер өчен генә эшләнгән.

**ПОКА'ЗЫВАТЬ** *несов.* — к. показать. ◇ **Глаз (или носа) не показывать** — күзгә дә күренмәү.

**ПОКА'ЗЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. показаться 2, 3; 2. *страд.* күрсәтелү, күрсәтеп бирелү; аңлатылу.

**ПО-КАКО'ВСКИ** — к. каковский.

**ПОКАЛИ'ТЬ** *несов. разг.* — бераз кыздыру, бераз кыздырып алу; 2. бераз кыздырып киптерү (чикләвекне); 3. бераз чыныктырып алу (тимерне).

**ПОКА'ЛЫВАТЬ** *несов. разг.* — 1. к. поколоть; 2. яргалау, яргалаштыру; *он изредка покалывает дрова* — ул сирәк-мирәк утын яргалый.

**ПОКАЛЯ'КАТЬ** *сов. простореч. фам.* — бераз сөйләшеп алу; бераз гәпләшеп алу, бераз ләчтит сату; *покалякали и разошлись* — бераз сөйләшеп алдык та таралыштык.

**ПОКА'МЕСТ** *нареч.* и *союз. простореч.* — әлегә, хәзергә, ...-ганчы; *покамест время есть* — әлегә вакыт бар; *покамест они не пришли, посидим в саду* — алар килгәнче бакчада утырып торыйк.

**ПОКАНИФО'ЛИТЬ** *сов.* — бераз сәмих-

ләү, бераз сәмихләп алу, бераз канифольләү, бераз канифоль сөртеп алу.

**ПОКАНЮ'ЧИТЬ** *сов. простореч.* — бераз сорану, (бераз вакыт) зарланып теләнү, (бераз вакыт) зарланып сорану.

**ПОКА'ПАТЬ** *сов. разг.* — 1. (азрак) тамызып алу, бераз тамызып алу, бераз тамызу; *покапай одеколону на платок* — кулъяулыкка азрак одеколон тамыз; 2. тамгалап алу, төшкәләп тору, тамчылап тору; *дождь покапал и перестал* — яңгыр тамчылап торды да туктады.

**ПОКА'ПЧИВАТЬ** I *несов. разг. фам.* — тәтәү, тәтәштергәләү, сөремләү, сөремләштергәләү; *лампы покапчивают* — лампалар бераз тәтиләр.

**ПОКА'ПЧИВАТЬ** II *несов. разг. фам.* — к. покоптить.

**ПОКА'ПЫВАТЬ** I *несов. разг.* — тамгалап тору, тамгалау, тамгалаштыру, бераз тамчылап тору; *с утра покапывало, а потом ливень начался* — иртән тамгалап кына тора иде, ә соңыннан коеп ява башлады.

**ПОКА'ПЫВАТЬ** II *несов. разг.* — казыштыру, казыштыргалау; *покапывать огородные грядки* — бакча түтәлләрен казыштыргалау.

**ПОКАРА'ТЬ** *сов. книжн.* — к. карать.

**ПОКАРАУ'ЛИТЬ** *сов. разг.* — бераз саклап тору, каравыллап тору, күз-колак булып тору; *покараулить вещи* — әйберләрне бераз саклап тору.

**ПОКА'РКАТЬ** *сов.* — бераз каркылдап тору; *покаркала ворона и улетела* — карга (бераз) каркылдап торды да очып китте.

**ПОКА'РМЛИВАТЬ** *несов. разг.* — ашаткалау, сирәк-мирәк ашату, аз-маз ашату.

**ПОКА'Т** *м. простореч.* — к. покатость.

**ПОКАТА'ТЬ** *сов.* — 1. бераз утыртып йөртү (атта, машинада һ. б.); *покатать детей на автомашине* — балаларны бераз автомашинага утыртып йөртү; 2. *разг.* бераз тәгәрәтеп алу; *покатать шары на бильярде* — бильярдта бераз шар тәгәрәтеп алу.

**ПОКАТА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. бераз утырып йөрү; *покататься на такси* — бераз таксига утырып йөрү; 2. бераз шуу; *покататься на санках* — бераз чана шуу.

**ПОКА'ТИСТЫЙ** *простореч.* — к. покатый.

**ПОКАТИ'ТЬ** *сов.* — 1. тәгәрәтеп җибәрү; *покатить бревно* — бүрәнәне тәгәрәтеп җибәрү; 2. *разг. фам.* китеп бару; *он покатил в город* — ул шәһәргә китеп барды.

**ПОКАТИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. тәгәрәп китү; *шар покатился по полу* — шар идән буйлап тәгәрәп китте; 2. *разг.* тәгәрәп төшеп китү, шуып төшеп китү; *покатиться с горы кубарем* — таудан мәтәлеп төшеп китү. ◇ **Покатиться со смеху** *разг.* — эче катып көлә башлау, тәгәри-тәгәри көлә башлау.

**ПОКА'ТОМ** *нареч. разг.* — сөзәкләнеп; *поле идёт покатом* — басу сөзәкләнеп бара.

**ПОКА'ТОСТЬ** *ж.* — сөзәклек.

**ПОКА'ТЫВАТЬ** *несов. разг.* — утыртып йөрткәләү (атта, машинада һ. б.).

**ПОКА'ТЫЙ** — сөзәк; *покатая местность* — сөзәк урын, сөзәк җир.

**ПОКАЧА'ТЬ** *сов.* — 1. бераз качать итеп алу; *покачать воду* — бераз су качать итеп алу; 2. бераз тирбәтү, бераз тирбәтеп тору; *покачать ребёнка* — баланы бераз тирбәтеп тору; 3. селкеп кую, чайкап кую; *покачать головой* — башны селкеп кую; 4. бераз атындыру; атындырып алу; *покачать ребёнка на качелях* — баланы бераз таганда атындыру.

**ПОКАЧА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — бераз атыну, бераз атынып алу; *покачаться на качелях* — бераз таган атыну.

**ПОКА'ЧИВАТЬ** *несов.* — селкеп тору, чайкап тору, селкеп-селкеп кую; *покачивать головой* — башны селкеп-селкеп кую.

**ПОКА'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. чайкалып тору, тирбәнеп тору; *лодка покачивалась на волнах* — көймә дулкында чайкалып тора иде; 2. ава-түнә бару, алпан-тилпән бару; *он шёл, покачиваясь* — ул ава-түнә бара иде.

**ПОКАЧНУ'ТЬ** *сов.* — селкетеп кую, селкетеп җибәрү.

**ПОКАЧНУ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. чайкалып китү, тирбәнеп китү, селкенеп китү; *он покачнулся и упал* — ул чайкалып китте дә егылды; 2. кыйшаю; *лачуга покачнулась в сторону* — алачык бер якка кыйшайган; 3. *перен. разг.* какшап китү, начарланып китү; *его дела покачнулись* — аның эшләре какшап китте, аның эшләре начарланып китте.

**ПОКА'ШЛИВАТЬ** *несов.* — йөткергәләштерү, йөткергәләү, йөткереп-йөткереп кую.

**ПОКА'ШЛЯТЬ** *сов.* — 1. берничә тапкыр йөткерү, берничә тапкыр тамак кырып кую; 2. (бераз) йөткерү, йөткереп авыру; *ребёнок несколько дней покашлял* — бала берничә көн йөткерде.

**ПОКАЯ'НИЕ** *ср.* — 1. *книжн.* хаталарын тану, гаебен тану, тәүбә, тәүбә итү, тәүбәгә килү; 2. *церк.* гөнаһларын сөйләп бирү (попка); 3. *дореввол. церк.* тәүбә иттерү, тәүбә иттерү җәзасы бирү (суд карары белән); *приговорить к церковному покаянию* — чиркәүдә тәүбә иттерергә дип карар чыгару. ◇ **Отпустить душу на покаяние** *разг. шутл. устар.* — тынычлык бирү, борчымау (кемне дә булса).

**ПОКАЯ'ННЫЙ** *церк. книжн.* или *ирон.* — тәүбә итү... -ы; *покаянная речь* — тәүбә итү сүзләре.

**ПОКА'ЯТЬСЯ** *сов.* — 1. к. каяться; 2. *разг. шутл.* сер итеп (үзенең гаебен) сөйләп бирү.

**ПОКВИТА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. *(отдать долг сполна)* (бурычны) кайтарып бирү; (бурычны) түләп бетерү; 2. *перен.* үч алу, үч кайтару, исәпләшү; *мы с тобой ещё поквитаемся* — без синең белән исәпләшербез әле.

**ПОКИВА'ТЬ** *сов.* — селеккәләү, каккалау; селкеп-селкеп кую; *покивать головой* — башны селкеп-селкеп кую.

**ПОКИДА'ТЬ** I *сов. разг.* — к. побросать.

**ПОКИДА'ТЬ** II *несов.* — к. покинуть.

**ПОКИ'ДЫВАТЬ** *несов.* — ыргыткалаштыру, аз-мазлап ыргыту, аз-мазлап ташлау.

**ПОКИ'НУТЬ** *сов.* — 1. ташлап китү, калдырып китү, китү; *покинуть свой дом* — үз өеңне ташлап китү; 2. ташлау, ташлап китү; *покинуть службу* — хезмәтне ташлау. ◇ **Его покинул рассудок** — ул акылыннан язды. **Его покинуло счастье** — бәхет аңа аркасы белән борылды. **Покинуть надежду** *устар.* — өмет өзү. **Покинуть постель** — урыннан тору. **Силы покинули меня** — көчем бетте, җегәрем бетте.

**ПОКИПЕ'ТЬ** *сов.* — бераз кайнау, бераз кайный төшү; *суп пусть покипит ещё* — аш (тагы) бераз кайный төшсен әле.

**ПОКИПЯТИ'ТЬ** *сов.* — бераз кайнату, кайната төшү, кайнату, кайнатып алу; *покипятить молоко подольше* — сөтне озаграк кайнату.

**ПОКИПЯТИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. к. покипеть; 2. *перен.* кызып китү; бераз кызып алу, чәпчеп китү; *сначала он покипятился было, а потом согласился с нами* — башта ул чәпчеп киткән иде дә, соңыннан безнең белән килеште.

**ПОКЛАДА'Я: не покладая рук** — бертуктамый, тырышып, армый-талмый; *работать не покладая рук* — бертуктамый эшләү, тырышып эшләү, армый-талмый эшләү.

**ПОКЛА'ДИСТОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.* — килешүчән булу, күндәмлек, юл куючанлык, сүзгә күнүчәнлек; *покладистость характера* — характерның килешүчән булуы.

**ПОКЛА'ДИСТЫЙ** — килешүчән, тыңлаучан, юл куючан, сүзгә күнүчән, күндәм, уңайлы; *покладистый человек* — сүзгә күнүчән, килешүчән кеше, күндәм кеше.

**ПОКЛА'ЖА** *ж. мн.* нет — йөк, багаж; *тяжёлая поклажа* — авыр йөк.

**ПОКЛА'СТЬ** *сов. простореч.* — төяү, тутыру, салу; *вещи поклали в сундук* — әйберләрне сандыкка тутырдылар; *на дровни поклали дрова* — чанага утын төяделәр.

**ПОКЛЕВА'ТЬ** *сов.* — 1. (чукып) чүпләп бетерү; *воробьи поклевали все вишни* — чыпчыклар чияләрнең барысын да (чукып) чүпләп бетергәннәр; 2. *(немного съесть, клюя)* (бераз) чукып ашау, азрак чүпләү, чукыштыру (кошлар турында); 3. *(несколько раз клюнуть)* — чиртү, чирткәләү, чиртеп-чиртеп кую (балык турында).

**ПОКЛЕВЕТА'ТЬ** *сов.* — бераз яла ягу, берникадәр яла ягу, яла ягып карау.

**ПОКЛЁВКА** *ж. мн.* нет, *спец.* — чиртү (балык турында); *сегодня ни одной поклёвки!* — бүген балык бер дә чиртмәде, бүген бер балык та чиртмәде.

**ПОКЛЁВЫВАТЬ** *несов.* — 1. азлап-азлап кына чуку, азлап-азлап кына чүпләү; 2. чирткәләү; *рыба поклёвывает* — балык чирткәли.

**ПОКЛЁП** *м. простореч.* — яла, әләк; *возводить поклёп* — яла ягу.

**ПОКЛЕПА'ТЬ** I *сов. тех.* — (бераз вакыт) клёпкалау, чүкеп беркетү; *поклепать котёл* — казанны бераз клёпкалау.

**ПОКЛЕПА'ТЬ** II *сов. обл.* — яла ягу, өстеннән сөйләү; *его совсем напрасно поклепали* — аңа бер дә юкка гына яла яктылар.

**ПОКЛЁПЩИК** *м.*, **ПОКЛЁПЩИЦА** *ж. простореч.* — яла ягучы.

**ПОКЛИ'КАТЬ** *сов. обл. простореч.* — кычкырып чакыру, чакыру; *маменька, покличьте её* — әнкәй, чакырыгыз аны.

**ПОКЛО'Н** *м.* — 1. *(приветствие)* сәлам бирү, баш ию; *сделать поклон при встрече* — очрашканда сәлам бирү, очрашканда баш ию; 2. *перен. устар.* *(покорная просьба)* ялыныч, үтенеч; 3. сәлам; *передайте поклон* — сәлам әйтегез. ◇ **Идти на поклон** *неодобр.* — ялагайланып баш ию, барып йөз суы түгү. **Идти с поклоном** *неодобр.* — ялвару, ялварып сорау, түбәнсенеп үтенү.

**ПОКЛОНЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книжн.* — 1. к. поклоняться; 2. *(преклонение)* сукырларча иярү, баш ию, табыну; *поклонение авторитетам* — авторитетларга табыну, авторитетларга сукырларча ияру.

**ПОКЛОНИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. баш иеп исәнләшү, баш ию, сәлам бирү; *снял шляпу и поклонился* — эшләпәсен салды да башын иеп исәнләште; 2. *редко (начать поклоняться)* табына башлау, бик югары дип исәпләү, бик кадерле дип санау.

**ПОКЛО'ННИК** *м.* — 1. хөрмәтләүче, баш июче, олылаучы; *поклонник Пушкина* — Пушкинны хөрмәтләүче; 2. *(влюблённый, ухаживатель)* сөеп йөрүче, сөюче; гашыйк; 3. *книжн. устар.* табынучы; *поклонники Будды* — Буддага табынучылар.

**ПОКЛО'ННИЦА** *ж.* — к. поклонник.

**ПОКЛО'ННЫЙ** *устар. нар.-поэт.* — тыңлаучан, буйсынучан.

**ПОКЛОНЯ'ТЬСЯ** *несов. книжн.* — 1. табыну; *поклоняться огню* — утка табыну; 2. *перен.* баш ию, табыну; *поклоняться таланту писателя* — язучының талантына баш ию.

**ПОКЛЯ'НЧИТЬ** *сов. разг. фам.* — теләнү, бераз теләнеп алу, сорану.

**ПОКЛЯ'СТЬСЯ** *сов.* — к. клясться.

**ПОКОБЕ'НИТЬСЯ** *сов. простореч.* — бераз кәҗәләнү, бераз кәҗәләнеп тору, бераз киреләнү, бераз киреләнеп тору, бераз тискәреләнеп тору.

**ПОКОВА'ТЬ** *сов.* — чүкү, бераз чүкеп алу, таптау, бераз таптап алу (тимерне).

**ПОКОВЕ'РКАТЬ** *сов. разг.* — бераз яньчү, бераз вату; *снарядом поковеркало повозку* — снаряд тиеп повозканы бераз ватты.

**ПОКО'ВКА** *ж. тех.* — 1. *только ед.* к. ковка; 2. чүкеп эшкәртелгән металл кисәге; *стальные поковки* — чүкеп эшкәртелгән корыч кисәкләре.

**ПОКОВЫЛЯ'ТЬ** *сов. разг.* — (бераз вакыт) чатанлап йөрү, (бераз вакыт) аксаклап йөрү; чатанлап китеп бару, аксаклап китеп бару.

**ПОКОВЫ'РИВАТЬ** *несов. разг.* — казыштыргалау, чокыштыргалау, сирәк-мирәк

казу, сирәк-мирәк чоку; *поковыривать в зубах* — теш казыштыргалау.

**ПОКОВЫРЯ'ТЬ** *сов. разг.* — бераз казу, бераз казып алу, бераз казыштыргалау, бераз чокыштыру.

**ПОКО'ИТЬ** *несов. устар.* — кадер-хөрмәт күрсәтү, күңелен күрү, хәтерен саклау; тынычлыгын саклау; *покоить родителей в старости* — карт көннәрендә ата-анага кадер-хөрмәт күрсәтү.

**ПОКО'ИТЬСЯ** *несов.* — 1. *книжн.* өстендә тору; *это сооружение покоится на каменном фундаменте* — бу корылма таш фундамент өстендә тора; 2. нигезләнү; *ленинизм покоится на гранитной базе марксизма* — ленинизм марксизмның гранит базасына нигезләнгән; 3. *устар.* (*отдыхать*) ял итү; 4. *устар.* тыныч яту (кабердә); *покойся, юноша-поэт* — тыныч ят, яшь шагыйрь; 5. күмелү; *здесь покоится прах поэта* — монда шагыйрь күмелгән.

**ПОКО'Й** *м.* — 1. *только ед. физ.* тынлык, тынычлык, тик торыш, хәрәкәтсезлек; *абсолютного покоя в природе нет* — табигатьтә абсолют хәрәкәтсезлек юк; *вывести тело из состояния покоя* — җисемне тынычлык хәленнән чыгару; 2. тынычлык, тынлык; *больному нужен покой* — авыруга тынычлык кирәк; 3. *устар.* бүлмә; *в пустых покоях дворца* — сарайның буш бүлмәләрендә. ◇ **Вечный покой** — үлем. **Жить на покое** — отставкада булу. **Удалиться на покой** *устар.* — отставкага чыгу. **Оставить в покое** — борчымау, тимәү. **Приёмный покой** — приемный покой (больницада авыруларга беренче ярдәм күрсәтү һәм палаталарга билгеләү бүлмәсе).

**ПОКО'ЙНИК** *м.*, **ПОКО'ЙНИЦА** *ж.* — 1. үлек, мәет; *покойника похоронили* — мәетне күмделәр; 2. мәрхүм; *покойник был хороший человек* — мәрхүм яхшы кеше иде.

**ПОКО'ЙНИЦКАЯ** *ж.* в *знач. сущ.* — үлекләр куя торган бина.

**ПОКО'ЙНИЦКИЙ** — 1. мәет төсле, үлек төсле, мәет төсе кергән, үлек төсе кергән; *покойницкий вид* — үлек төсе кергән кыяфәт.

**ПОКО'ЙНЫЙ** — 1. тыныч, юаш, сабыр; *покойный ребёнок* — тыныч бала; 2. хәрәкәтсез; *его физиономия редко оставалась покойною* — аның йөзенең хәрәкәтсез булган чагы бик сирәк иде; 3. иппе, уңайлы, җайлы; *покойное кресло* — уңайлы кресло; 4. мәрхүм; *покойный мой друг* — минем мәрхүм дустым. ◇ **Покойной ночи** *разг.* — тыныч йокы. **Будь покоен, будьте покойны** *разг.* — 1. тыныч бул(ыгыз); 2. *разг.* кот тә тор, һичшиксез, әлбәттә; *будь покоен, он сдержит своё слово* — һичшиксез, ул үз сүзендә торыр.

**ПОКОЛА'ЧИВАТЬ** *несов.* — сирәк-мирәк кыйнаштыргалау, сирәк-мирәк суккалаштыру; *в детстве его поколачивали* — бала чагында аны сирәк-мирәк кыйнаштыргалыйлар иде.

**ПОКОЛДОВА'ТЬ** *сов.* — сихерләп алу, им-том итеп алу.

**ПОКО'ЛЕ** *союз устар. обл.* — ...-га кадәр,...-ганчы; *поколе не умру* — үлгәнгә кадәр, үлгәнче.

**ПОКОЛЕБА'ТЬ** *сов.* — к. колебать.

**ПОКОЛЕ'НИЕ** *ср.* — 1. буын; *третье поколение* — өченче буын; *молодое поколение* — яшь буын; 2. *устар.* (*род, племя*) кабилә, оруг, токым; 3. замандаш; *пушкинское поколение* — Пушкин замандашлары. ◇ **Из поколения в поколение** — 1. нәселдән нәселгә; атадан балага; 2. буыннан буынга (традиция буенча).

**ПОКОЛЕСИ'ТЬ** *сов. разг.* — аркылыга-буйга йөреп чыгу, бик күп йөрү; *поколесил я по белу свету* — мин дөньяны аркылыга-буйга йөреп чыктым, җир йөзендә мин бик күп йөрдем, мин дөнья гиздем.

**ПОКОЛЕ'ТЬ** *сов. просторен.* — к. околеть.

**ПОКОЛОТИ'ТЬ** *сов.* — 1. *разг.* (*сильно побить*) тукмау, дөмбәсләү; 2. *разг.* шакылдату, кагу; *поколоти в ворота, авось услышат* — капкаларын шакылдат, бәлки ишетерләр; 3. *просторен.* ватып бетерү, кырып бетерү; *всю посуду поколотил* — бөтен савыт-сабаны кырып бетерде.

**ПОКОЛОТИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. ватылу, ватылып бетү; *яйца поколотились в ящике* — йомыркалар ящикта ватылып беткән; 2. изелү, изелеп бетү; *яблоки поколотились* — алмалар изелеп беткән.

**ПОКОЛО'ТЬ** *сов.* — 1. (*уколоть в нескольких местах*) чәнечкәләү, чәнчештерү, чәнчеп чыгу, бернчә тапкыр чәнчеп алу; 2. *безл.* чәнчешү; *ночью у меня в боку покололо* — төнлә минем янбашым чәнчеште; 3. ярып алу, ярып бетерү, ватып алу, ваклап алу; *надо поколоть сахару* — шикәр ватып алырга кирәк; *поколол все дрова* — барлык утынны ярып бетердем.

**ПОКОЛУПА'ТЬ** *сов. разг.* — бераз чокып алу, бераз куптарып алу.

**ПОКОЛУ'ПЫВАТЬ** *несов. разг.* — чокып алгалау, куптарып алгалау.

**ПОКО'ЛЬ** *нареч. устар. обл.* — к. поколе.

**ПОКОМА'НДОВАТЬ** *сов.* — бераз командовать итеп алу.

**ПОКО'МКАТЬ** *сов. просторен.* — 1. йомарлап бетерү; *всё платье покомкали* — күлмәкне бөтенләй йомарлап бетергәннәр; 2. йомарлап тору, бераз йомарлап тору.

**ПОКОНОПА'ТИТЬ** *сов. спец.* — бераз конопатить итеп алу, бераз мүкләп алу (тишек, ярык урыннарга сүс, чүбек, мүк кебек әйберләр кыстырып чыгу).

**ПОКОНЧА'ТЬ** *сов. разг.* — бетереп чыгу, тәмамлау (төрле вакытта); *все они уже покончали курсы* (*Чехов*) — алар барысы да курсларны бетереп чыкты инде.

**ПОКО'НЧИТЬ** *сов.* — 1. (*довести до конца*) бетерү, тәмамлау, очына чыгу; 2. бетерү, юк итү; *покончить с классовым врагом* — сыйнфый дошманны юк итү. ◇ **Покончить с собой или с жизнью** *ритор.* — үзен-үзе үтерү. **Покончено** (*у кого*

*с кем.) безл.* — ара өзелде, мөнәсәбәт бетте; *у меня с ним всё покончено* — минем аның белән ара өзелде.

**ПОКОПА'ТЬ** *сов.* — бераз казу, бераз казый төшү; *надо глубже, покопай ещё* — тирәнрәк кирәк, тагы бераз казый төш.

**ПОКОПА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — казынып-чокынып тору, казынып тору; *покопайся ещё немного, и опоздал бы* — тагын бераз казынып торган булса, соңга калган булыр иде.

**ПОКОПТЕ'ТЬ** *сов.* — сөремләү, сөремләп алу, төтәү, төтәп алу; *лампа немного покоптела* — лампа бераз сөремләп алды.

**ПОКОПТИ'ТЬ** *сов.* — бераз каклап алу, каклый төшү; *мясо надо ещё покоптить* — итне тагын бераз каклый төшәргә кирәк.

**ПОКОРЁЖИТЬ** *сов. просторeч.* — бераз калҗайту, кәкрәйтеп бетерү, бөкрәйтеп бетерү.

**ПОКОРЁЖИТЬСЯ** *сов. просторeч.* — бераз калҗаю; *обложка книги покорёжилась* — китапның тышы бераз калҗайган.

**ПОКОРИ'ТЕЛЬ** *м.*, **ПОКОРИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж. книж.* — сугышып алучы, басып алучы, буйсындыручы, яулап алучы; *Наполеона называли покорителем Европы* — Наполеонны Европаны яулап алучы дип атыйлар иде. ◇ **Покоритель сердец** *шутл. ирон.* — хатын-кызларның йөрәген яндыручы, хатын-кызларның йөрәгенә ут салучы. **Покорительница сердец** *шутл. ирон.* — ирләрнең башын әйләндерүче хатын-кыз, ирләрне үзенә гашыйк итүче хатын-кыз.

**ПОКОРИ'ТЬ** I *сов.* — **1.** яулап алу, басып алу, сугышып алу, көчләп буйсындыру; *покорить страну* — илне яулап алу; 2. җиңү, буйсындыру; *покорить природу* — табигатьне җиңү; 3. кулга ияләштерү; *покорить зверя* — ерткыч хайванны кулга ияләштерү; 4. (*внушить к себе симпатию*) үзенә карату, үзенә караттыру.

**ПОКОРИ'ТЬ** II *сов. устар.* — бераз битәрләү, бераз әрләү, бераз шелтәләү, бераз битәрләп алу, бераз шелтәләп алу.

**ПОКОРИ'ТЬСЯ** *сов.* — буйсыну, баш ию, килешү, бирелү, юл кую; *покориться судьбе* — язмышка буйсыну.

**ПОКОРМИ'ТЬ** *сов.* — ашату, ашатып алу, бераз ашату; *покормить ребёнка* — баланы ашатып алу.

**ПОКОРМИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — ашау, ашап алу, туену.

**ПОКО'РНЕЙШЕ** *нареч.*: **покорнейше прошу** — түбәнчелек белән үтенәм; рәхим итегез; *покорнейше благодарю (офиц.)* — түбәнчелек белән рәхмәт укыйм; бик зур рәхмәт.

**ПОКО'РНО** *нареч.* — буйсынып, баш иеп, түбәнчелек белән. ◇ **Покорно благодарю** *перен. разг.* — юк инде, рәхмәт; *нет уж, благодарю покорно, я на это не пойду* — юк инде, рәхмәт тәкъдимегезгә, мин ул эшне эшли алмыйм.

**ПОКО'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет — буйсынучанлык, сүз тыңлаучанлык, күндәмлек, буйсыну; *изъявить покорность* — буйсынучанлык күрсәтү.

**ПОКО'РНЫЙ** — тыңлаучан, карусыз, буйсынучан, күндәм. ◇ **Ваш покорный слуга** *устар.* — сезне хөрмәтләүче, сезне хөрмәтләп калучы (хат азагында язылa). **Слуга покорный** *разг. ирон.* — мин сезгә кол түгел, миннән булмый инде; *каждый день бегать за тобой — слуга покорный!* — синең артыннан йөгереп йөрергә калса — миннән булмый инде. **Покорная просьба** *офиц. устар.* — үтенеп сорау.

**ПОКОРО'БИТЬ** *сов.* — к. коробить.

**ПОКОРО'БИТЬСЯ** *сов.* — к. коробиться.

**ПОКО'РСТВОВАТЬ** *несов. книж. устар.* — буйсыну, баш ию, ярарга тырышу; *и море и суша покорствуют нам* (*Батюшков*) — коры җир дә, диңгез дә безгә буйсына.

**ПОКОРЫ'СТОВАТЬСЯ** *сов. устар.* — 1. (*поживиться*) файдалану; 2. күзе кызыгу, кызыгу; *покорыстоваться на чужое добро* — кеше малына кызыгу.

**ПОКОРЯ'ТЬ** *несов.* — к. покорить I.

**ПОКОРЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. покориться; 2. *страд.* буйсындырылу; үзенә каратылу.

**ПОКО'С** *м.* — **1.** *только ед.* (*действие*) печән чабу; 2. печән өсте, печән чабу вакыты; *приближается покос* — печән өсте житә; 3. болын; *богатые колхозные покосы* — колхозның бай болыннары.

**ПОКОСИ'ТЬ** I *сов.* — 1. к. выкосить; 2. бераз (печән) чабу, бераз чабып алу; *надо пойти покосить* — барып бераз чабарга кирәк.

**ПОКОСИ'ТЬ** II *сов.* — **1.** кыйшайту, кыйшайтып кую, кыегайту, кыегайтып кую, чалшайту, чалшайтып кую; 2. *безл.* кыйшаю; *оконную раму покосило* — тәрәзә рамасы кыйшайган.

**ПОКОСИ'ТЬСЯ** *сов.* — **1.** кырын карап кую; 2. (*провести некоторое время, косясь*) бераз кырын карап тору; 3. кыйшаю, кыегаю; *дверь покосилась* — ишек кыйшайган.

**ПОКО'СНИК** *м. обл.* — печән чабучы, иген чабучы, чабучы.

**ПОКО'СНЫЙ** — 1. печән чабу...-ы; *покосное время* — печән чабу вакыты; 2. печәнлек...; *покосные луга* — печәнлек болыннар.

**ПОКОЧЕВА'ТЬ** *сов.* — (берникадәр вакытны) күчеп йөреп үткәрү, урыннан-урынга күчеп йөрү.

**ПОКОЧЕВРЯ'ЖИТЬСЯ** *сов. просторeч.* — бераз киреләнү, бераз кәҗәләнү, киреләнеп алу, кәҗәләнеп алу.

**ПОКРА'ЖА** *ж. офиц.* — 1. (*действие*) к. красть; 2. урланган әйберләр; *покража отыскалась* — урланган әйберләр табылды.

**ПОКРА'ПАТЬ** *сов.* — 1. бераз сибәләү, сибәләп алу, сибәләп китү; *дождь покрапал* — яңгыр бераз сибәләп китте; 2. бөркеп сипкелләндерү (мәсәлән, ак стенага буяу тамчылары бөркеп бөрчекле-бөрчекле төскә кертү); 3. (*провести некоторое время, крапая*) бераз сибәләп алу, бераз сибәләп тору.

**ПОКРА'ПЫВАТЬ** *несов.*— аз-маз сибәләү, аз-маз сибәләп тору, тәшкәләп тору, бераз пыскаклап тору; *всю ночь покрапывал дождь* — төн буе аз-маз яңгыр сибәләп торды.

**ПОКРА'СИТЬ** *сов.*— 1. буяу, буяп чыгу, буяп жибәрү; *покрасить крышу* — өй түбәсен буяп жибәрү; 2. манып алу, мандырып алу; *покрасить платье* — күлмәкне манып алу.

**ПОКРА'СКА** *ж. мн.* нет, *спец.*— буяу; *покраска крыши заняла три дня* — өй түбәсен буяу өч көнгә сузылды.

**ПОКРАСНЕ'ТЬ** *сов.*— кызарып китү.

**ПОКРАСОВА'ТЬСЯ** *сов.*— купшыланып йөрү, матурланып йөрү, (берникадәр вакыт) кыланып йөрү, масаеп йөрү; *покрасоваться перед женщинами* — хатын-кызлар алдында матурланып йөрү.

**ПОКРА'СТЬ** *сов. разг.*— урлау (күп итеп), урлап бетерү; *все вещи покрали* — бар әйберне урлап бетерделәр.

**ПОКРАХМА'ЛИТЬ** *сов.*— 1. бераз крахмаллау; *покрахмалить бельё* — керне бераз крахмаллау; 2. крахмаллап берникадәр вакытны үткәрү.

**ПОКРЕХТЕ'ТЬ** *сов. разг.*— к. покряхтеть.

**ПОКРЁХТЫВАТЬ** *несов. разг.*— к. покряхтывать.

**ПОКРИВИ'ТЬ** *сов.*— к. кривить.

**ПОКРИВИ'ТЬСЯ** *сов.*— к. кривиться 1.

**ПОКРИВЛЯ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— боргаланып алу, кыланып алу.

**ПОКРИ'КИВАТЬ** *несов. разг.*— 1. кычкыргалау, кычкырып-кычкырып кую; *больной иногда покрикивал* — авыру кайчакта кычкырып-кычкырып куя иде; 2. кычкырыну, сирәк-мирәк кычкырынып алу, жикеренү, акыру, бакыру (вакыт-вакыт).

**ПОКРИТИКОВА'ТЬ** *сов. разг.*— 1. тәнкыйтьләп алу, тәнкыйть итеп алу; 2. бераз тәнкыйтьләп тору, тәнкыйть итеп тору.

**ПОКРИЧА'ТЬ** *сов.*— бераз кычкыру, кычкыру; *пришлось немало покричать в лесу, созывая отставших* — артта калган кешеләрне чакырып, урманда шактый озак кычкырырга туры килде.

**ПОКРО'В** I *м.*— 1. *книж.* каплам; *снежный покров* — кар капламы; 2. (*покрывало*) япма, жәймә. ◇ **Взять под свой покров** *кого-н.*— кемне дә булса үз канатың астына алу, яклау. **Под покровом ночи** *поэт.*— төн караңгылыгы белән файдаланып, төн караңгылыгыннан файдаланып. **Волосяные покровы** — чәч, йон, төк. **Наружные покровы** — тире.

**ПОКРО'В** II *м. мн.* нет, *церк.*— покрау көне (иске стиль белән 1 октябрьда христианнарның дини бәйрәме).

**ПОКРОВИ'ТЕЛЬ** *м.*, **ПОКРОВИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж.*— яклаучы, канат астына алучы, химаяче.

**ПОКРОВИ'ТЕЛЬСТВЕННЫЙ** *книж. ирон.*— яклый торган, яклаган; *он говорил покровительственным тоном* — ул яклый торган тон белән сөйләде. ◇ **Покровительственная система** — к. протекционизм. **Покровительственная окраска** — к. мимикрия.

**ПОКРОВИ'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет — яклау, канат астына алу, химая; *оказывать покровительство кому-н., чему-н.*— берәр кешене, берәр нәрсәне үз канаты астына алу, яклау. ◇ **Под покровительством** — таянып; *под покровительством закона* — законга таянып.

**ПОКРОВИ'ТЕЛЬСТВОВАТЬ** *несов. устар.*— яклау, саклау, канат астына алу; *покровительствовать родственникам* — кардәшләрне яклау.

**ПОКРО'ВНЫЙ** — каплый торган, саклый торган; *покровные ткани* — каплый торган тканьнар. ◇ **Покровные растения** *с.-х.*— каплама үсемлекләр (күпьеллык азык үләннәре үсешенә уңай йогынты ясый торган көчлерәк, чыдамлырак үсемлекләр, мәсәлән, клеверның яхшы үсүе өчен уңай йогынты ясый торган солы һәм арыш).

**ПОКРОИ'ТЬ** *сов.*— кием кисү; кием кисеп үткәрү (бераз вакытны).

**ПОКРО'Й** *м.*— фасон, калып, өлге; *шинель военного покроя* — гаскәри фасондагы шинель. ◇ **Человек старинного покроя** — иске заман кешесе, борынгы йолаларны, гадәтләрне саклаучы кеше. **На покрой** *разг.*— жаена, көенә; *всё у него в доме на свой покрой* — аның өендә бөтен нәрсә үз жаена корылган. **На один покрой** *перен.*— бер калыпка сугылган.

**ПОКРО'МА** и **ПОКРО'МКА** *ж. спец.*— кырый, чит, материя кырые.

**ПОКРОМСА'ТЬ** *сов. простореч.*— к. искромсать.

**ПОКРОПИ'ТЬ** *сов.*— 1. бөркеп чылатып алу, чәчрәтеп чылатып алу, сиптереп чылатып алу; 2. сибәләп явып алу (яңгыр турында).

**ПОКРОШИ'ТЬ** *сов.*— бераз турау, бераз ваклау; *покрошить хлеба в суп* — ашка бераз ипи турау.

**ПОКРУГЛЕ'ТЬ** *сов.*— к. круглеть.

**ПОКРУЖИ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. берничә тапкыр әйләнү, берничә тапкыр тирәли әйләнү, әйләнеп чыгу; 2. адашып йөрү; *уж мы и покружили, пока не выбрались на дорогу* — юл тапканчы, без бик озак адашып йөрдек; 3. *фам.* йөреп чыгу, әйләнеп чыгу, ил гизү; *покружить по всему свету* — бөтен дөньяны йөреп чыгу; 4. (берникадәр вакыт) әйләндереп тору, бөтереп тору, әйләндереп алу, бөтереп алу.

**ПОКРУЖИ'ТЬСЯ** *сов.*— бераз әйләнү, берничә тапкыр әйләнү, берничә тапкыр бөтерелү; *акробат покружился на трапеции и спрыгнул* — акробат трапециядә бераз әйләнде дә сикереп төште.

**ПОКРУПНЕ'ТЬ** *сов. разг.*— бераз эреләнү, бераз зураю, бераз эреләнә төшү.

**ПОКРУТИ'ТЬ** *сов.*— 1. бераз бөтерү, бераз бөтереп кую; *покрутить ус* — мыекны бераз бөтереп кую; 2. бераз әйләндерү; *покрутить ручку веялки* — жилгәргечнең тоткасын бераз әйләндерү.

**ПОКРУТИ'ТЬСЯ** *сов.* — бераз әйләнү, бераз бөтерелү.

**ПОКРУЧИ'НИТЬСЯ** *сов. просторечь.* — бераз кайгыру, бераз хәсрәтләнү, бераз кайгы-хәсрәткә бирелү, бераз кайгы-хәсрәт чигү.

**ПОКРЫВА'ЛО** *ср.* — бөркәнчек, япма, япкыч, җәймә; *покрывало для постели* — түшәк япмасы; *она шла под белым покрывалом* — ул ак бөркәнчек бөркәнеп бара иде.

**ПОКРЫВА'ТЬ** *несов.* — 1. к. покрыть; 2. *спорт.* (*о беге лошади*) — арт аякларын алгы аяк эзләренә басып чабу, эзгә эз басып чабу.

**ПОКРЫВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. покрыться; 2. *страд.* ябылу, капланылу; 3. *перен. книж.* туры килү, бәрабәр булу, бер булу; *сущность предмета не покрывается его названием* — предметның асылы аның исеме белән бәрабәр түгел.

**ПОКРЫ'ТИЕ** *ср.* — 1. (*действие*) к. покрыть; 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7; 2. каплау; *покрытие расходов* — расходларны каплау; *покрытие звезды луной* — айның йолдызны каплавы; 3. каплама, ябу материалы; түшәмә, түшәү материалы; *асфальтовое покрытие дороги* — юлның асфальт түшәмәсе; *черепица прочное и дешёвое покрытие для построек* — черепица — корылма түбәләрен ябу материалларының ныгы һәм арзанлысы; 4. *бухг.* расходларны каплый торган акча; *покрытие по счёту выслано* — счёт буенча расходларны каплау өчен (тиешле) акча җибәрелде.

**ПОКРЫТОСЕМЕ'ННЫЕ** и **ПОКРЫТОСЕМЯ'ННЫЕ** *бот.* — ябык орлыклылар, ябык орлыклы үсемлекләр.

**ПОКРЫ'ТЫЙ** — ябылган, капланган. ◇ **Покрыто мраком неизвестности** — бернәрсә дә билгеле түгел, караңгы.

**ПОКРЫ'ТЬ** *сов.* — 1. каплау, ябу, җәю; *покрыть стол скатертью* — өстәлгә эскәтер җәю; *покрыть ребёнка одеялом* — балага юрган ябу; *облака покрыли небо* — күк йөзен болытлар каплады; 2. тышлау; *покрыть мебель материей* — мебельне материя белән тышлау; *покрыть шубу сукном* — тунны постау белән тышлау; 3. тутыру; *царский министр Столыпин покрыл виселицами страну* — патша министры Столыпин илне дар агачлары белән тутырды; 4. каплау, йөгертү, сөртү, буяу; *покрыть позолотой* — алтын йөгертү; *покрыть мебель лаком* — мебельгә лак сөртү; 5. ясау, төшерү; *покрыть обложку рисунками* — китап тышына рәсемнәр ясау; 6. түләү; *покрыть долг* — бурычны түләү; 7. тәэмин итү; *лесная промышленность покрыла потребности городов в топливе* — урман промышленносте шәһәрләрнең ягулыкка булган ихтыяҗларын тәэмин итте; 7. *перен.* яшерү; *покрыть грех* — гөнаһны яшерү; 8. (*о звуках*) басу; *голос оратора покрыл шум в зале* — ораторның тавышы залдагы шау-шуны басты; 9. *просторечь.* оту, җиңү; *я в шахматах всякого покрою* — шахмат уенында мин теләсә кемне җиңәм; 10. *вульг. просторечь.* кискен рәвештә тәнкыйтьләү, сүгү, тиргәү; *покрыть плохого докладчика* — начар докладчыны кискен рәвештә тәнкыйтьләү; 11. *спорт.* үтү; *лыжник покрыл дистанцию в 10 минут* — чаңгычы дистанцияне ун минутта үтте; 12. *спец.* каплату, чаптыру; *покрыть кобылу* — бияне чаптыру. ◇ **Он покрыл себя славой** — ул үзенә дан казанды. **Покрыть тайной** — серле итү, яшерү.

**ПОКРЫ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. ябыну, бөркәнү; *покрыться одеялом* — юрган ябыну; *покрыться платком* — яулык бөркәнү; 2. *перен.* каплану, томалану; *небо покрылось тучами* — күк йөзе болытлар белән капланды. ◇ **Щёки покрылись румянцем** — яңаклары алсуланып китте.

**ПОКРЫ'ШЕЧНЫЙ** — тышлык...; *покрышечный материал* — тышлык материал.

**ПОКРЫ'ШКА** *ж.* — 1. *разг.* капкач; *покрышка для горшка* — чүлмәк капкачы; 2. покрышка, тышлык; *автомобильная шина состоит из покрышки и камеры* — автомобиль шины камерадан һәм покрышкадан гыйбарәт; *покрышка мяча* — туп тышлыгы; 3. *порт.* тышлык, өслек (кием тышлыгы); 4. *разг.* (переплёт) китап тышы. ◇ **Ни дна, ни покрышки** — *бран. просторечь.* — җир упкыры, дөмеккере.

**ПОКРЯ'КАТЬ** *сов. разг.* — 1. бакылдап алу (үрдәк); *утки покрякали и смолкли* — үрдәкләр бакылдап алдылар да тындылар; 2. тамак кырып алу (кеше).

**ПОКРЯ'КИВАТЬ** *несов. разг.* — 1. бакылдап-бакылдап кую, сирәк-мирәк бакылдау; 2. (сирәк-мирәк) тамак кырып кую, тамак кыргалау.

**ПОКРЯХТЕ'ТЬ** *сов. разг.* — бераз ухылдау, бераз ыңгырашу.

**ПОКРЯ'ХТЫВАТЬ** *несов. разг.* — ыңгыраштыргалау, ухылдаштыргалау.

**ПОКУВЫРКА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — мәтәлчек атынгалап алу.

**ПОКУ'ДА** *нареч.* и *союз. разг.* — к. пока.

**ПОКУДА'ХТАТЬ** *сов. просторечь.* — кыткылдап алу, кытаклап алу (тавык).

**ПОКУ'ДОВА** *нареч. союз. разг.* — к. пока.

**ПОКУКОВА'ТЬ** *сов.* — (кәк-күк дип) кычкырып алу, бераз кычкырып алу (күке).

**ПОКУМЕ'КАТЬ** *сов. обл.* — уйлап карау, фикер йөртеп карау.

**ПОКУМИ'ТЬСЯ** *сов. обл.* — к. кумиться.

**ПОКУПА'ТЕЛЬ** *м.* — 1. сатып алучы, алучы; 2. *только. ед. собир.* сатып алучылар, алучылар.

**ПОКУПА'ТЕЛЬНИЦА** *ж.* — к. покупатель 1.

**ПОКУПА'ТЕЛЬНЫЙ** *экон.* — сатып алу...-ы; *покупательная способность населения* — халыкның сатып алу сәләте.

**ПОКУПА'ТЕЛЬСКИЙ** — сатып алучы...-ы; сатып алучылар...-ы; *покупательские интересы* — сатып алучыларның интереслары.

**ПОКУПА'ТЬ I** *несов.* — к. купить.

**ПОКУПА'ТЬ II** *сов. разг.* — коендырып алу, юындырып алу; *покупать ребёнка в ванне* — баланы ваннада юындырып алу.

**ПОКУПА'ТЬСЯ** I *несов. страд.*— 1. сатып алыну; 2. ирешелү; *великая награда покупается только высоким нравственным достоинством* — бөек бүләккә югары әхлакый сыйфат белән генә ирешелә (ирешергә мөмкин).

**ПОКУПА'ТЬСЯ** II *сов.*— су коенып алу.

**ПОКУ'ПКА** *ж.*— 1. *только ед. (действие)* к. покупать I; 2. сатып алынган әйбер, товар. ◇ **Поехать за покупками** — кирәк-яракны сатып алырга бару.

**ПОКУПНО'Й** — 1. сатып алынган; *покупной хлеб* — сатып алынган икмәк; 2. *редко (продажный)* сатлык, сатыла торган, сатып алынуы мөмкин булган; 3. к. покупательный.

**ПОКУ'ПЩИК** *м.*, **ПОКУ'ПЩИЦА** *ж.*— сатып алучы; *найти покупщика* — сатып алучыны табу.

**ПОКУРА'ЖИТЬСЯ** *сов. разг.*— бераз бәйләнчекләнеп алу, бераз үз сүзләнеп алу, бераз кыланып алу, бераз тыйнаксызланып алу, бераз тискәреләнеп алу, бераз тәртипсезләнеп алу, бераз тупас кыланып алу, кешене мыскыл итеп алу.

**ПОКУ'РИВАТЬ** *несов. разг.*— тәмәке тарткалаштыру, сирәк-мирәк тәмәке тарткалау; *он ещё продолжает покуривать* — ул һаман тәмәке тарткалаштыра әле.

**ПОКУРИ'ТЬ** *сов.*— 1. (тәмәке) тартып алу; *давай покурим* — әйдә (тәмәке) тартып алыйк; 2. к. курить 2.

**ПОКУРОЛЕ'СИТЬ** *сов. разг.* — дау куптарып алу, гауга чыгарып алу, ыгы-зыгы килеп алу, җәнҗал чыгарып алу.

**ПОКУСА'ТЬ** *сов.*— талау, тешләү; *его покусала бешеная собака* — аны котырган эт талаган.

**ПОКУСИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. теләп карау, тырышып карау, маташып карау; *покуситься на кражу* — урларга теләп карау; 2. хаслану, кул сузу; *покуситься на чужое имущество* — кеше милкенә кул сузу; 3. *(попытаться убить)* үтерергә теләү, һөҗүм итәргә теләү; 4. *шутл.* чакыру, тарту, тартырга тырышу; *затевая концерт, вздумали покуситься на знаменитого баритона* — концерт оештырып, атаклы баритонны тартырга уйладылар.

**ПОКУ'СЫВАТЬ** *несов. разг.*— тешләштергәләү, сирәк-мирәк тешләп алу; *блохи покусывают* — борчалар тешләштергәли.

**ПОКУТИ'ТЬ** *сов. разг.*— әйттереп алу, типтереп алу.

**ПОКУ'ШАТЬ** *сов.*— 1. *(поесть)* ашап алу; 2. *(кончить есть)* ашап бетерү.

**ПОКУША'ТЬСЯ** *несов.*— к. покуситься.

**ПОКУШЕ'НИЕ** *ср.*— теләү, теләп карау, маташып карау; ... -мәкче булу; *покушение на убийство* — үтерергә маташып карау, үтермәкче булу. ◇ **Покушение с негодными средствами** *перен. книж.*— нигезсез теләк, яраксыз омтылыш.

**ПОЛ** I *м.*— идән.

**ПОЛ** II *м.*— җенес (ир яки хатын; ата хайван яки ана хайван). ◇ **Прекрасный пол** *шутл.*— хатын-кызлар.

**ПОЛ** III *м. нескл.*— ярты; *пол пятого* — бишенче ярты.

**ПОЛА'** *ж.*— чабу, итәк; *правая пола* — уң чабу. ◇ **Из под полы** *разг.*— итәк астыннан (яшертен, астыртын).

**ПОЛАВИ'РОВАТЬ** *сов.*— бераз лавировать итү.

**ПОЛАГА'ТЬ** *несов.*— 1. уйлау, фараз итү, исәпләү, ... дип санау, ... дип белү, ... дип уйлау; *мы полагали, что он уже уехал* — без ул киткәндер инде дип уйлаган идек; *полагать больным* — авыру дип белү, авыру дип санау; 2. *книж.* кую; *полагать конец* — чик кую; 3. *устар. торж. ритор.* салу; *полагать в гроб* — табутка салу. ◇ **Надо полагать** *в знач. вводн. сл.*— уйларга кирәк, бәлки, ахры, ихтимал; *надо полагать, он уже не придёт* — ул килмәстер инде ахры. **Полагать начало** — башлап җибәрү.

**ПОЛАГА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. положиться; 2. тиеш булу; *по должности мне полагалось следить за порядком* — вазыйфам буенча мин тәртип сакларга тиеш идем. ◇ **Здесь курить не полагается** — биредә тәмәке тартырга ярамый.

**ПОЛА'ДИТЬ** *сов.*— татулашу, уртак фикергә килү, килешү; *мы с ним поладим* — без аның белән килешербез.

**ПОЛА'ДКА** *ж. обл.*— төзәтү, җайлау, ипләү, рәтләү.

**ПОЛА'ЗАТЬ** *сов.*— к. лазить.

**ПОЛА'ЗИТЬ** *сов.*— к. лазить.

**ПОЛА'ИВАТЬ** *несов. разг.*— өргәләштерү (эт турында әйтелә).

**ПОЛАКА'ТЬ** *сов. разг.* — ялап алу, бераз ялап алу, бераз эчеп алу (эт, мәче турында).

**ПОЛАКИРОВА'ТЬ** *сов.*— бераз лаклау, бераз лак сөртү, лак сөртеп ялтыратып алу.

**ПОЛА'КОМИТЬ** *сов.*— бераз сыйлау, бераз тәмле нәрсәләр ашату.

**ПОЛА'КОМИТЬСЯ** *сов.*— 1. сыйлану, сыйланып алу, тәмле әйберләр ашап алу; тәмле тамакланып алу; 2. файдаланып калу (үзеңнеке булмаган әйбердән).

**ПОЛА'МЫВАТЬ** *несов. безл. разг.*— тәннәр авыртып тору, сызлап тору; *меня что-то поламывает, уж не простудился ли я?* — салкын тимәдеме икән, тәннәрем авыртып тора.

**ПОЛАСКА'ТЬ** *сов.*— бераз сөеп алу, бераз иркәләп алу, бераз сөю, бераз иркәләү.

**ПОЛАСКА'ТЬСЯ** *сов.*— бераз иркәләнү, бераз иркәләнеп алу.

**ПОЛА'ТИ** *ед.* нет — сәндерә.

**ПОЛА'ЯТЬ** *сов.*— 1. бераз өрү, бераз өреп алу; *на краю деревни полаяла собака и смолкла* — авыл читендә бераз эт өрде дә туктады; 2. *(поругать, позлословить) простореч.* тиргәү, өрү, чәйнәү.

**ПОЛА'ЯТЬСЯ** *сов. простореч. вульг.* — кычкырышып алу, тиргәшеп алу, әрләшеп алу; бераз кычкырышу, бераз тиргәшү, бераз әрләшү.

**ПО'ЛБА** *ж. мн.* нет — борай.

**ПОЛБЕДЫ'** *в знач. сказ. разг.*— ярты бәла; зур каза түгел; әллә ни зур бәла түгел; *деньги вытащили из кармана — это*

*ещё полбеды* — кесәдән акчаны алганнар — анысы әллә ни зур каза түгел.

**ПО'ЛБЕННЫЙ** *спец.*— борай ...-ы; *полбенная крупа* — борай ярмасы.

**ПОЛБУТЫ'ЛКА** *ж. простореч.*— к. полбутылки.

**ПОЛБУТЫ'ЛКИ** *ж.*— ярты шешә, ярты бутылка.

**ПОЛВЕ'КА** *м.*— ярты гасыр; *прошло полвека* — ярты гасыр үтте.

**ПОЛГА'ТЬ** *сов. разг.*— бераз ялган сөйләү, бераз ялганлашу, бераз алдашу.

**ПОЛГО'ДА** *м.*— ярты ел; *через полгода* — ярты ел үткәч, ярты елдан (соң).

**ПОЛГО'ЛОСА** *м.*— к. вполголоса.

**ПОЛГО'РОДА** *м.*— ярты шәһәр, шәһәрнең яртысы; *полгорода знает об этих происшествиях* — бу вакыйгаларны ярты шәһәр белә.

**ПОЛГО'РЯ** *разг. в знач. сказ.*— зур каза түгел, ярты кайгы, ярты хәсрәт, ярты бәла.

**ПОЛДЕ'ЛА** *ср. разг.*— ярты эш, эшнең яртысы; *ещё и полдела не сделал, а уж вечер* — эшнең яртысын да эшләп бетерә алмадым, кич тә җитте (эшнең яртысы да эшләнмәде, кич тә җитте).

**ПО'ЛДЕНЬ** *м.*— 1. *только ед.* көн уртасы, төш, төш вакыты; 2. *только ед. перен. поэт. (середина жизненного пути)* тормыш уртасы, ярты гомер; гомер яртысы; 3. *обл. только мн.* сыер сава торган урын (көн уртасында); *коров погнал с полдён* — сыер сава торган урыннан сыерларны куып алып китте.

**ПОЛДНЕ'ВНЫЙ** — 1. ярты көнлек; *полдневный заработок* — ярты көнлек хезмәт хакы; 2. көн уртасындагы, төш вакытындагы, төшке; *полдневный жар* — көн уртасындагы эсселек.

**ПО'ЛДНИК** *м. обл.* — кичке әбәт, төштән соңгы җиңелчә аш (көндезге аш белән кичке аш арасында).

**ПО'ЛДНИЧАТЬ** *несов. обл.*— төшке аш ашау, әбәт ашау.

**ПОЛДНЯ'** *м.* — ярты көн; *прошло полдня* — ярты көн үтте.

**ПОЛДОРО'ГИ** *ж.*— ярты юл; *уже полдороги проехали* — ярты юлны үттек инде. ◇ **На полдороге** *перен.*— ярты юлда (туктап калу) (башлаган эшне бетермичә).

**ПОЛДЮ'ЖИНЫ** *ж.*— ярты дюжина (алты данә).

**ПО'ЛЕ** *ср.*— 1. басу, кыр; *ржаное поле* — арыш басуы; 2. *(ровное, обширное пространство)* ялан, дала; 3. *перен.* җирлек, фон; *олень на золотом поле* — алтын фонга төшерелгән болан рәсеме; 4. кыр, чит; *тетрадь без полей* — кыр калдырылмаган дәфтәр; *поля шляпы* — эшләпә чите; 5. мәйдан; *поле боя* — сугыш мәйданы; *широкое поле деятельности* — киң эш мәйданы; 6. *физ.* кыр; *магнитное поле* — магнит кыры; 7. *истор. (судебный поединок в древней Руси)* судлашу, суд аркылы дәгъвалашу; 8. ау, ау сезоны; *посмотрим, каковы будут собаки в поле* — этләрнең нинди икәнен ауга чыккач күрербез. ◇ **С полем!** — яхшы табыш белән! (аучыларга карата әйтелә). **Поле зрения** — күз күреме, күрү мәйданы. **Один в поле не воин** — к. один.

**ПОЛЕБЕЗИ'ТЬ** *сов. разг. пренебр.*— бераз ялагайланып алу, бераз тәлинкә тотып алу.

**ПОЛЕВА'ТЬ** *несов. охот. устар.*— к. охотиться.

**ПОЛЕВЕ'ТЬ** *сов.*— к. леветь.

**ПОЛЁВКА** *ж. зоол.*— кыр тычканы.

**ПОЛЕВО'Д** *м.* — кыр(чылык) эшләре белгече, агроном.

**ПОЛЕВО'ДСТВО** *ср. с.-х.*— кырчылык.

**ПОЛЕВО'ДЧЕСКИЙ** *с.-х.*— кырчылык...-ы; кыр эшләре...-ы; *полеводческие бригады* — кырчылык бригадалары.

**ПОЛЕВО'Й** — 1. кыр ...-ы; *полевые цветы* — кыр чәчәкләре; *полевые работы* — кыр эшләре; 2. *воен.* сугыш мәйданындагы; *полевые войска* — сугыш мәйданындагы гаскәрләр; 3. хәрби; *полевая почта* — хәрби почта. ◇ **Полевая сумка** *воен.*— полевой сумка (карта, компас һ. б. салып йөртә торган махсус сумка).

**ПОЛЕГА'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *с.-х.*— сөрлегүе, сөрлегү дәрәҗәсе, егылуы, егылу дәрәҗәсе; *полегаемость хлебов* — ашлыкларның сөрлегү дәрәҗәсе.

**ПОЛЕГА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *с.-х.*— сөрлегү, егылу; *полегание хлебов* — ашлыкларның сөрлегүе.

**ПОЛЕГА'ТЬ** *несов. книж.*— к. полечь 2, 3.

**ПОЛЕГО'НЬКУ** *нареч. простореч.*— 1. акрын гына, ашыкмыйча, җайлап кына, иплэп кенә; *лошадей не гони, а поезжай полегоньку* — атларны кума, ашыкмыйча гына бар; 2. *перен. ирон.* акрынлап, бер көйгә; *полегоньку да помаленьку* — акрынлап һәм бер көйгә.

**ПОЛЕГЧА'ТЬ** и *обл.* **ПОЛЕ'ГЧИТЬ** *сов. безл. простореч.*— җиңеләю, җиңеләя төшү, җиңеләеп китү; *больному с утра полегчало* — авыруның иртәдән башлап хәле җиңеләя төште.

**ПОЛЕДЕНЕ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. бозлану, бозга әйләнү; 2. туңу, өшү; *её руки и ноги поледенели* — аның аяк-куллары туңган.

**ПОЛЕЖА'ЛОЕ** *офиц. в знач. сущ.*— саклаган өчен түләнә торган акча, алмый торган өчен түләнә торган акча (почтада посылка, станциядә йөк һ. б. турында).

**ПОЛЕЖА'ЛЫЙ** — *разг.* озак яткан озак ятып бозылган; *полежалая мука* — озак ятып бозылган он.

**ПОЛЕЖА'ТЬ** *сов. разг.*— бераз ятып тору, ятып алу; *полежать на кровати* — кроватьта бераз ятып тору, бераз кроватьта ятып алу.

**ПОЛЁЖИВАТЬ** *несов. разг.*— яткалау, яткалаштырып тору, ята-тора йөрү; *он всё полёживает, ещё не выходит по ле болезни* — авырудан соң ул һаман чыкмый әле, яткалаштырып тора.

**ПОЛЕЗА'Й** *пов. накл. просторечи.*— кер, мен. ◇ **Назвался груздём — полезай в кузов** *(пословица)* — тәртә арасына кергәч, тарта алмыйм дип әйтмә.

**ПОЛЕ'ЗНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.*— файдалылык; *нужно проверить полезность этого мероприятия* — бу чараның файдалылыгын тикшереп карарга кирәк.

**ПОЛЕ'ЗНЫЙ — 1.** файдалы; *полезные растения* — файдалы үсемлекләр; 2. файдаланырга яраклы, файдалы, кирәкле; *полезная жилая площадь* — файдаланырга яраклы торак мәйданы; *полезные ископаемые* — файдалы казылмалар.

**ПОЛЕ'ЗТЬ** *сов. разг.*— 1. менү, менеп китү; *мальчик полез на дерево* — малай агачка менеп китте; 2. керү, кереп китү; *стадо в сад полезло* — көтү бакчага кереп китте; 3. *простореч. пренебр.* тотыну, башлау; *полез в драку* — сугыша башлады; 4. тыгу, тыгылу; *он полез в карман за деньгами* — акча алыр өчен ул кулын кесәсенә тыкты; 5. коелу; *после болезни у меня волосы полезли* — авырудан соң минем чәчләрем коела башлады. ◇ **В голову её полезли всякие несообразности** (Чехов) — аның башына төрле юк-бар уйлар килә башлады.

**ПОЛЕМИЗИ'РОВАТЬ** *несов. книж.*— бәхәсләшү, сүз көрәштерү, полемикага керешү; *полемизировать с докладчиком* — докладчы белән сүз көрәштерү.

**ПОЛЕ'МИКА** *ж. книж.*— полемика, бәхәс, сүз көрәштерү; *научная полемика* — гыйльми бәхәс.

**ПОЛЕМИ'СТ** *м.*, **ПОЛЕМИ'СТКА** *ж. книж.*— полемист (бәхәсләшергә, сүз көрәштерергә ярата торган кеше, бәхәсләшергә оста кеше).

**ПОЛЕМИ'ЧЕСКИЙ** *книж.*— 1. полемик; *полемическое выступление* — полемик чыгыш; 2. к. полемичный.

**ПОЛЕМИ'ЧНЫЙ** — сүз көрәштерә торган, бәхәсләшә торган; *полемичный тон* — сүз көрәштерә торган тон.

**ПОЛЕ'НИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— бераз ялкаулану; *школьник стал полениваться* — мәктәп баласы бераз ялкаулана башлады.

**ПОЛЕНИ'КА** *ж.*— поленика (мүк җиләгенең бер төре).

**ПОЛЕНИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. бераз ирену, бераз ялкаулану, авырсыну; *не поленитесь зайти завтра ещё раз* — иртәгә тагын бер кат кереп чыгарга авырсынмагыз инде; 2. бераз вакыт ялкаулану, ялкаулыкка сабышып яту.

**ПОЛЕ'НИ'ЦА** *ж. нар.-поэт.*— 1. баһадир, каһарман (рус эпосында); 2. *устар. обл.* (*ватага удальцов*) кыю кешеләр төркеме.

**ПОЛЕ'ННИЦА** *ж.*— эрдәнә.

**ПОЛЕ'НО** *ср.*— 1. бер пүлән, бер агач утын; 2. *охот.* бүре койрыгы.

**ПОЛЕПЕТА'ТЬ** *сов.*— бераз такылдап алу, бераз бытылдап алу, бераз лыкылдау.

**ПОЛЕПИ'ТЬ** *сов.*— бераз сылап алу, бераз әвәләп алу, сылап ясый-ясый бераз вакыт үткәрү, әвәләп ясый-ясый бераз вакыт үткәрү.

**ПОЛЕ'ПЛИВАТЬ** *несов. разг.*— әвәләп ясаштыргалау; *сынишка мой полепливает статуйки* — минем улым әвәләп статуйкалар ясаштыргалый.

**ПОЛЕСО'ВЩИК** *м. обл.*— урман каравылчысы, урман сакчысы.

**ПОЛЕ'СЬЕ** *ср. мн.* нет — иңкүлектәге вак урман, урманлы уйсулык, әрәмәлек.

**ПОЛЁТ** *м.*— 1. очу; *полёт снаряда* — снарядның очуы; *уток бьют на полёте* — үрдәкләрне очканда аталар; 2. *только мн.* очыш; *полёты не состоялись из-за дурной погоды* — һава начар булу сәбәпле, очышлар үткәрелмәде. ◇ **С птичьего полёта** — 1. бик югарыдан карап; 2. *разг. ирон.* эшне аңлап җиткермичә, эшкә төшенмичә, өстән карап, бармак аша карап. **Высокого полёта птица** *разг. устар.*— зур дәрәҗәле кеше. **Полёт мысли** *или* **фантазии** *книж. ритор. ирон.*— фикернең көчлелеге, фикерләрнең көчле булуы, фикерләр омтылышы, фантазиягә бай булу. **Видна птица по полёту** — кем икәнлеге әллә кайдан күренеп тора (кыланышыннан кем икәнлеге күренеп тора).

**ПОЛЕТА'ТЬ** *сов.*— бераз очып йөрү, бераз очу; *хочется полетать на аэроплане* — бераз аэропланда очып йөрисе килә.

**ПОЛЕТЕ'ТЬ** *сов.*— 1. очып китү; *ворона полетела в лес* — карга урманга очып китте; 2. *перен.* чабу, йөгерү, йөгереп китү; *мы полетели со всех ног* — без җанфәрманга чаптык; 3. *разг. фам.* төшү, егылу, егылып төшү, төшеп китү, егылып китү; *тарелка полетела и разбилась* — тәлинкә төшеп китте дә ватылды; *я поскользнулся и полетел* — мин таеп киттем дә егылдым; *полететь с лошади* — ат өстеннән егылып төшү; *гвоздь погнулся, и полка полетела* — кадак бөгелде дә, шүрлек төшеп китте.

**ПОЛЁТНЫЙ** *спец.*— 1. очу...-ы; *полётные свойства самолёта* — самолётның очу сыйфатлары; 2. очкандагы; *полётный вес бомбовоза* — бомбовозның очкандагы авырлыгы.

**ПОЛЕТУ'ХА** *ж. зоол.*— к. летяга.

**ПОЛЕ'ЧИВАТЬ** *несов. разг.*— дәвалаштыру, дәвалаштыргалау.

**ПОЛЕ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— дәвалангалау, ара-тирә дәвалану.

**ПОЛЕЧИ'ТЬ** *сов.*— бераз дәвалау, бераз дәвалап алу.

**ПОЛЕЧИ'ТЬСЯ** *сов.*— бераз дәвалану, бераз дәваланып алу; *вам необходимо полечиться* — сезгә бераз дәваланырга кирәк.

**ПОЛЕ'ЧЬ** *сов.*— 1. ятып бетү; *все уже спать полегли* — барысы да йокларга ятып беттеләр инде; 2. *ритор.* кырылу, үлү; *в боях на Карпатах полегло много народу* — Карпат тавындагы сугышларда бик күп халык кырылды; 3. сәрләгү (игеннәр); *после ливня рожь полегла* — коеп яуган яңгырдан соң, арыш сәрләккән.

**ПОЛЖИ'ЗНИ** *ж.*— ярты гомер.

**ПО'ЛЗАТЬ** *несов.*— 1. үрмәләп йөрү, шуышып йөрү, шуышу, үрмәләү; *насекомые ползают* — бөҗәкләр үрмәләп йөриләр; *ребятишки ползают по полу* — балалар идәндә шуышып йөриләр; 2. *перен. презрит.* (*подличать, пресмыкаться*) ярарга тырышу, ялагайлану, тәлинкә тоту. ◇ **Ползать в ногах** *презрит. ритор.*— аягына егылу, табанын ялау.

**ПОЛЗКО'М** *нареч.*— үрмәләп, шуышып; *двигаться ползком* — үрмәләп бару, шуышып бару.

**ПОЛЗО'К** *м.*— шуышу; *в два ползка добрался до куста* — ике шуышуда куакка барып җиттем.

**ПОЛЗТИ'** *несов.*— 1. үрмәләү, шуышу, үрмәләп бару, шуышып бару, шуышып килү, шуышып китү; *клоп ползёт по стене* — кандала стена буйлап үрмәләп бара; 2. *перен. разг.* бик акрын бару; бик акрын килү; 3. *перен.* агылу; *тучи ползли по небу* — күктә болытлар агыла иде; 4. *перен.* уралып үсү, үрмәләү, үрмәләп үсү; *по решёткам забора полз хмель* — койма рәшәткәләренә уралып колмак үсә иде; 5. агу, агып төшү, тамып-тамып тору; *по лицу ползли капли крови* — битеннән кан тамчылары агып төшә иде; 6. ташып чыгу, ташып түгелү; *тесто ползёт из квашни* — күәс чиләгеннән камыр ташып чыга; 7. *перен. разг.* таралу; *ползут слухи, один другого нелепее* — берсеннән-бер е мәгънәсезрәк хәбәрләр тарала; 8. җимерелү, ишелү; *берег ползёт* — яр җимерелә; *почва ползёт* — туфрак ишелә; 9. кубу; *кожа ползёт* — кабыгы куба, тиресе куба; 10. *разг. (о ткани)* таралып китү, сыпылу; *тронешь иглой — оно уже и ползёт* — энә тигерттең исә, ул сыпыла башлый. ◇ **Ползать на четвереньках** — мүкәләп йөрү.

**ПОЛЗУ'Н** *м.*— 1. *разг.* шуышып йөрүче, үрмәләп йөрүче; 2. *тех.* ползун (машиналарның һәм двигательләрнең эшләгән чагында берәр юнәлеш өстендә алга-артка шуып йөри торган өлеше).

**ПОЛЗУНО'К** *м.*— 1. *разг.* шуышып йөрүче, үрмәләп йөрүче (кеше һәм хайван балалары турында әйтелә); 2. к. ползун 2.

**ПОЛЗУ'ЧИЙ** — 1. шуышып йөри торган, үрмәләп йөри торган; *ползучий гад* — шуышып йөри торган хәшәрәт; 2. *бот.* үрмәле, уралып үсә торган; *ползучие растения* — үрмәле үсемлекләр; 3. шуып төшә торган, шуыша торган; *ползучие льды* — шуып төшә торган бозлар, шуыша торган бозлар.

**ПО'ЛИ...**— кушма сүзләрдә күп мәгънәсен белдерә торган кыскартма, мәсәлән, полиглот — күп тел белүче кеше.

**ПОЛИАНДРИ'Я** *ж. этнол.*— күп ирлелек (полигамиянең бер төре, бер хатынның берничә ир белән торуы).

**ПОЛИ'В** *м. мн.* нет, *спец.*— к. поливка.

**ПОЛИ'ВА** *ж. тех. мн.* нет — к. глазурь 1.

**ПОЛИВА'ЛЬЩИК** *м.*— су сибүче (урамнарга, гөлләргә).

**ПОЛИВА'ТЬ** *несов.*— к. полить.

**ПОЛИВА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. политься 1; 2. *страд.* су сибелү.

**ПЛОИ'ВКА** *ж. мн.* нет — к. полить 1.

**ПОЛИВНО'Й** *спец.*— су сибелә торган; *поливные участки* — су сибелә торган участоклар.

**ПОЛИ'ВОЧНЫЙ** — су сибә торган; *поливочные машины* — су сибә торган машиналар.

**ПОЛИГАМИ'ЧЕСКИЙ** *этнол.*— полигамия...-ы; полигамик; *полигамический обычай* — полигамия йоласы, полигамик йола.

**ПОЛИГА'МИЯ** *ж. мн.* нет, *этнол.*— полигамия (күп хатын алу яки күп ир белән тору йоласы).

**ПОЛИГА'МНЫЙ** *этнол.*— к. полигамический.

**ПОЛИГИ'НИЯ** *ж. мн.* нет, *этнол.*— 1. полигиния (күп хатын алу йоласы); 2. *бот.* күп җимешлелек (бер чәчәктә берничә җимешлек, аналык органының булуы).

**ПОЛИГЛО'Т** *м. книж.*— полиглот (күп телләр белүче, күп телләрдә сөйләшә белүче).

**ПОЛИГО'Н** *м.*— 1. *воен.* полигон (атарга өйрәнү мәйданы); *артиллерийский полигон* — артиллерия полигоны; 2. *мат. редко (многоугольник)* күппочмак.

**ПОЛИГОНА'ЛЬНЫЙ** *мат.*— күппочмаклы.

**ПОЛИГРА'Ф** *м. тех.*— полиграф (күчермәләр алу приборы).

**ПОЛИГРАФИ'СТ** *м.*— полиграфист (полиграфия эшчесе яисә белгече).

**ПОЛИГРАФИ'ЧЕСКИЙ** полиграфия...-ы; *полиграфическое производство* — полиграфия производствосы.

**ПОЛИГРАФИ'Я** *ж. мн.* нет — полиграфия (китап, журнал, газета бастыру производствосы).

**ПОЛИЗА'ТЬ** *сов.*—(берничә тапкыр) ялап алу; *собака полизала руку своего хозяина* — эт берничә тапкыр хуҗасының кулын ялап алды.

**ПОЛИ'ЗЫВАТЬ** *несов.*— ялаштыргалау, сирәк-мирәк ялаштыру.

**ПОЛИКЛИ'НИКА** *ж.*— поликлиника (төрле авыруларны карый һәм күп төрле юллар белән дәвалый торган учреждение).

**ПОЛИЛОВЕ'ТЬ** *сов.*— к. лиловеть.

**ПОЛИМЕ'НТ** *м. спец.*— полимент (лаклау алдыннан сөртелә торган махсус кызыл сыекча).

**ПОЛИМЕТАЛЛИ'ЧЕСКИЙ** — күп металлы; *полиметаллические руды* — күп металлы рудалар.

**ПОЛИМОРФИ'ЗМ** *м. мн.* нет — полиморфизм (1. *зоол. бот.* бер үк төрдә булган үсемлекләр яки терекләк ияләре арасында, мәсәлән, бал кортлары арасында, тәзелеш формасы ягыннан башкалардан аерыла торган индивидларның булуы; 2. *мин.* бер үк матдәнең төрле формада кристаллашу үзенчәлеге).

**ПОЛИМОРФИ'ЧЕСКИЙ, ПОЛИМО'РФНЫЙ** *науч.*— полиморфик, төрле формада очрый торган; *полиморфические растения* — полиморфик үсемлекләр; *полиморфные тела* — төрле формада очрый торган җисемнәр.

**ПОЛИНЕВА'ТЬ** *сов.* — к. полиновать.

**ПОЛИНЕЗИ'ЙЦЫ** *мн. (ед.* полинезиец)— полинезиялеләр (Полинезия утрауларында яшәүче халыклар).

**ПОЛИНОВА'ТЬ** *сов.*—(бераз вакыт) сызыклар сызу, (бераз вакыт) сызыклар сызып алу.

**ПОЛИНО'М** *м. мат.*— полином, күпбуын.

**ПОЛИНЯ'ЛЫЙ** *разг.*— уңган, төсе киткән, агарган; *полинялая занавеска* — уңган тәрәзә пәрдәсе.

**ПОЛИНЯ'ТЬ** *сов.*— к. линять.

**ПОЛИ'П** I *м.*— полип (кузгалмыйча бер җирдә яши торган диңгез хайваны, мәсәлән, мәрҗән).

**ПОЛИ'П** II *м.*— полип (лайлалы яры өстенә чыга торган бер төр шеш).

**ПОЛИРОВА'ЛЬНИК** *м. спец.*— шомарткыч.

**ПОЛИРОВА'ЛЬНЫЙ** — шомарту...-ы, шомарта торган; *полировальный станок* — шомарту станогы.

**ПОЛИРОВА'ТЬ** *несов.*— шомартып ялтырату, полировать итү; *полировать мебель* — мебельне шомартып ялтырату.

**ПОЛИРО'ВКА** *ж. мн.* нет — 1. *(действие)* к. полировать; 2. ялтыравык; *полировка на столе потрескалась* — өстәлнең ялтыравыгы чатнаган.

**ПОЛИРО'ВОЧНЫЙ** — ялтырата торган, ялтырату...-ы; *полировочный материал* — ялтырата торган материал; ялтырату материалы.

**ПОЛИРО'ВЩИК** *м.*— шомартып ялтыратучы.

**ПО'ЛИС** *м. офиц.*— полис (милекне, гомерне страховать итү турында бирелә торган рәсми документ).

**ПОЛИСА'ДНИК** — к. палисадник.

**ПОЛИСИНТЕТИ'ЧЕСКИЙ** *лингв.*— полисинтетик (аерым сүзләрнең тамырларын бер-беренә укмаштыру юлы белән сүзҗөмлә төзелә торган); *полисинтетические языки* — полисинтетик телләр.

**ПОЛИСМЕ'Н** *м.*— полисмен (Англиядә, АКШта полицейский).

**ПОЛИ'СТНЫЙ** — табак санына (башына) карап түләнә торган; *полистный авторский гонорар* — авторга табак санына карап түләнә торган гонорар.

**ПОЛИ'Т...**— кушма сүзләрдә „политик" мәгънәсен белдерә торган кыскартма, мәсәлән: *политработа* — политик эш.

**ПОЛИТГРА'МОТА** *ж. мн.* нет — политграмота (башлангыч политик белемнең кыскача курсы).

**ПОЛИТДЕ'НЬ** *м.* — политзанятие көне; политзанятие үткәрелә торган көн.

**ПОЛИТЕИ'ЗМ** *м. мн.* нет — политеизм (күп аллага ышану).

**ПОЛИТЕИ'СТ** *м. книж.*— политеизм тарафдары.

**ПОЛИТЕИСТИ'ЧЕСКИЙ** — политеистик; *политеистический взгляд* — политеистик караш.

**ПОЛИТЕХНИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — к. политехнизировать.

**ПОЛИТЕХНИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— политехниклаштыру, политехнизацияләү, политехнизм кертү; *политехнизировать школу* — мәктәпне политехниклаштыру.

**ПОЛИТЕХНИ'ЗМ** *м. мн.* нет — политехнизм (укучыларны теоретик яктан да, практик яктан да производствоның төп тармаклары белән таныштыруны күздә тоткан уку-укыту системасы).

**ПОЛИТЕ'ХНИК** *м.*— политехник (политехникум студенты яисә политехникум тәмам иткән инженер).

**ПОЛИТЕ'ХНИКУМ** *м.*— политехникум (төрле техник белем бирә торган урта һәм югары уку йортларының исеме).

**ПОЛИТЕХНИ'ЧЕСКИЙ** — политехника...-ы; *политехнический институт* — политехника институты.

**ПОЛИТЗАКЛЮЧЁННЫЙ** *м. нов.*— политик тоткын (капиталистик илләрдә политик гаеп белән гаепләнеп төрмәгә ябылган кеше).

**ПОЛИ'ТИК** *м.*— 1. политик, политик эшлекле; 2. политик (а. политика белән кызыксынучы; б. *перен. простореч. устар.* үзен тота белүче кеше, эшне йөртә белүче кеше).

**ПОЛИ'ТИКА** *ж. мн.* нет — политика (1. дәүләт властенең, берәр партиянең яки иҗтимагый группаның үз сыйнфый интересларын тормышка ашыруга юнәлдерелгән эшчәнлеге; 2. җәмәгать һәм дәүләт тормышына бәйле мәсьәләләр һәм вакыйгалар); 3. *перен. разг.* ният, хәйлә; *я твою политику насквозь вижу* — мин синең хәйләңне үтәдән-үтә күрәм.

**ПОЛИТИКА'Н** *м.*, **ПОЛИТИКА'НША** *ж.*— 1. *неодобр.* политикан (а. политикадагы төп бурычларны вак-төяк мәсьәләләргә кайтарып калдырып, үз файдасы өчен генә эш йөртүче кеше; б. *разг. ирон.* политик темаларга сөйләшергә яратучы кеше); 2. *разг. неодобр.* хәйләкәр, мәкерле кеше; 3. *простореч. устар. (вежливый, обходительный человек)* үзен-үзе тота белүче кеше.

**ПОЛИТИКА'НИТЬ** *несов. устар. разг. пренебр.*— к. политиканствовать.

**ПОЛИТИКА'НСТВО** *ср. мн.* нет, *неодобр.*— политиканлык (политикадагы төп бурычларны вак-төяк мәсьәләләргә кайтарып калдырып, үз файдасы өчен генә эш йөртү).

**ПОЛИТИКА'НСТВОВАТЬ** *несов. неодобр.*— политикан булу, политиканлык белән шөгыльләнү, политиканлыкка бирелү.

**ПОЛИТИКОВА'ТЬ** *несов. разг. устар.*— хәйләләү, икейөзлеләнү.

**ПОЛИТИПА'Ж** *м. тип. устар.*— 1. политипаж (агачтагы гравюрадан китапка басылган рәсем); 2. бер типтагы рәсемнәр, виньеткалар өчен клише.

**ПОЛИТИ'ЧЕСКИЙ** I — 1. политик; *политическая борьба* — политик көрәш; *политический строй* — политик строй; 2. *дореvол. разг.* политический (революцион көрәштә катнашкан өчен судка бирелгән яки кулга алынган кеше).

**ПОЛИТИ'ЧЕСКИЙ** II: политическая экономия — к. политэкономия. ◇ **Политическая смерть** *книж.*— политик үлем, политик һәм идея ягыннан юкка чыгу, политик банкрот булу.

**ПОЛИТИ'ЧНЫЙ** *разг.*— тактлы, оста, алдын-артын уйлап эш итә торган; ягымлы,

яхшы мөгамәләле, үзен-үзе тота белә торган, инсафлы; *политичный человек* — алдын-артын уйлап эш итә торган кеше.

**ПОЛИТКАТОРЖА'НИН** *м.*— политкаторжанин (патша хөкүмәте вакытында революцион эш өчен каторгада булган кеше).

**ПОЛИТМИ'НИМУМ** *м.*— политминимум (политик белемнәр минимумы).

**ПОЛИТО'Й** — к. политый.

**ПОЛИТОТДЕ'Л** *м.*— политотдел, политбүлек.

**ПОЛИТОТДЕ'ЛЕЦ** *м. нов.*— политотдел рәботнигы.

**ПОЛИТПРОСВЕ'Т** *м.*— политпросвет (1. политик аң-белем; 2. политик аң-белем тарату эше белән җитәкчелек итә торган орган).

**ПОЛИТРАБО'ТА** *ж. мн.* нет — политик эш (алып бару); *политработа в армии* — армиядә политик эш алып бару.

**ПОЛИТРЕДА'КТОР** *м.*— политик редактор.

**ПОЛИТРАБО'ТНИК** *м. полит.* — политработник (политик эш алып баручы).

**ПОЛИТРУ'К** *м.*— политрук (политик җитәкче, Совет армиясендә политик эш белән җитәкчелек итүче).

**ПОЛИТСОСТА'В** *м.*— политсостав.

**ПОЛИТУ'РА** *ж. мн.* нет — 1. политура, лак; 2. *разг.* к. полировка.

**ПОЛИТУЧЁБА** *ж. нов. мн.* нет, *разг.*— политучеба, политик уку, политик белем алу.

**ПОЛИТШКО'ЛА** *ж.* — политшкола, политик мәктәп, политик белем бирү мәктәбе.

**ПОЛИ'ТЫЙ** — коендырылган, ... сибелгән (су һ. б. ш. сыекча сибелгән).

**ПОЛИ'ТЬ** *сов.*— 1. сибү, су сибү; *полить растения* — үсемлекләргә су сибү; 2. ява башлау, коеп ява башлау; *видите, какой дождь полил* — күрәсезме, яңгыр нинди коеп ява башлады; 3. бераз яву, бераз явып алу; *дождь полил немножко и перестал* — яңгыр бераз явып алды да туктады.

**ПОЛИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. коену; өскә су кою; *политься водой из ведра* — чиләктән су белән коену; 2. ага башлау; *вода полилась из крана* — краннан су ага башлады; 3. *перен. разг.* ява башлау; *полились вопросы* — сораулар ява башлады; 4. *перен. разг.* агыла башлау; *полились задушевные речи* — чын күңелдән сөйләнгән сүзләр агыла башлады.

**ПОЛИТЭКОНО'М** *м. мн.* нет — политэконом (политик экономия белгече).

**ПОЛИТЭКОНО'МИЯ** *ж. мн.* нет — политэкономия (кешелек җәмгыяте үсешенең төрле баскычларында җитештерү һәм материаль байлыкларны бүлү законнарын, кешеләр арасындагы җитештерү мөнәсәбәтләре үсешенең, ягъни экономик мөнәсәбәтләр үсешенең законнарын өйрәнә торган иҗтимагый фән).

**ПОЛИФОНИ'ЧЕСКИЙ** *муз.*— полифоник, күп тавышлы; *полифоническая музыка* — полифоник музыка.

**ПОЛИФОНИ'Я** *ж. мн.* нет — полифония (күп тавышлылык).

**ПОЛИФТО'НГ** *м. лингв.*— полифтонг (янәшә торган берничә сузык авазлы иҗек).

**ПОЛИФТОНГИ'ЧЕСКИЙ** *лингв.*— полифтонгик; *полифтонгические звуки* — полифтонгик авазлар.

**ПОЛИЦЕ'ЙЩИНА** *ж.*— полицейщина (полиция режимы, иҗтимагый тормышны полиция күзәтүе астына алу).

**ПОЛИЦМЕ'ЙСТЕР** *м. устар. разг.*— полицмейстер (революциягә кадәр зур шәһәрләрдә полиция башлыгы).

**ПОЛИ'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — полиция (1. капиталистик илләрдә буржуаз тәртипне саклау органы; 2. полицейскийлардан торган кораллы отряд).

**ПО'МЕСЬ** *ж.*— 1. катнаш токым, кушылгак (төрле токым хайваннары кушылуыннан туган хайван, мәсәлән, качыр; яки төрле төр үсемлекләр кушылуыннан килеп чыккан үсемлек).

**ПОМЕ'СЯЧНЫЙ** — айлык, айлап түләнә торган, айлап бирелә торган, ай саен кабатлана торган; *помесячная зарплата* — айлап түләнә торган эш хакы; *помесячный доход* — айлык доход.

**ПОМЁТ** I *м. мн.* нет — 1. тизәк; *птичий помёт* — кош тизәге.

**ПОМЁТ** II *спец. мн.* нет — бер оя бала (эт, кролик кебек вак хайваннарның бер тудыруда китергән балалары). ◇ **Одного помёта** *простореч. вульг перен.*— бер атаана баласы, бертуганнар.

**ПОМЕ'ТА** *ж.*— билге, тамга; *делать пометы на полях книги* — китап читенә билгеләр кую.

**ПОМЕТА'ТЬ** I *сов.*— (бераз вакыт) ыргыту, бераз чөю; *пометать копьё* — бераз сөңге ыргыту.

**ПОМЕТА'ТЬ** II *сов.*— бераз типчү, бераз типчеп алу, күкләп алу.

**ПОМЕТА'ТЬСЯ** *сов.*— 1. бәргәләнү, бераз бәргәләнеп алу; тыпырчынып алу, бәрелеп-сугылып алу; *лисица пометалась в клетке и утихла* — төлке читлектә бераз бәргәләнеп алды да тынды; 2. *простореч.* (*метнуться*) ташлану, читкә ташлану, читкә тайпылу.

**ПОМЕ'ТИТЬ** *сов.*— билгеләү, билге салу, билге кую, тамга салу, тамгалау.

**ПОМЕ'ТКА** *ж.*— билге.

**ПОМЁТЫВАТЬ** I *несов. разг.*— ыргыткалаштыру, чөйгәләштерү.

**ПОМЁТЫВАТЬ** II *несов разг.*— типчештергәләү, сирәк-мирәк типчештерү, күкләштергәләү, вакыт-вакыт күкләү.

**ПОМЕ'ХА** *ж.*— комачаулык, кыенлык, тоткарлык, киртә.

**ПОМЕЧА'ТЬ** *несов.*— к. пометить.

**ПОМЕЧА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— билге куелу, билге куеп чыгылу, тамга салыну.

**ПОМЕЧТА'ТЬ** *сов.*— (бераз вакыт) хыяллапып алу, бераз хыяллану, бераз хыялга бирелү.

**ПОМЕ'ШАННЫЙ** I — 1. (*сумасшедший*) тилергән, акылдан язган, шашкан; 2. *перен. разг.* саташкан; *помешанный на музыке* — музыка белән саташкан.

**ПОМЕ'ШАННЫЙ** II — буталган, болгатылган.

**ПОМЕША'ТЕЛЬСТВО** *ср. книжс.*— акылдан язу, тилерү, юләрләнү.

**ПОМЕША'ТЬ** I *сов.*— комачаулау, борчу.

**ПОМЕША'ТЬ** II *сов.*— 1. болгатып алу; *помешать кашу* — ботканы болгатып алу; 2. бераз болгатып тору.

**ПОМЕША'ТЬСЯ** *сов.*— 1. (*сойти с ума*) акылдан язу, тилерү, юләрләнү; 2. *перен.* саташу, бирелеп китү, мавыгу; *помешаться на лошадях* — атлар белән мавыгу.

**ПОМЕ'ШИВАТЬ** I *несов.*— вакыт-вакыт болгату, болгаткалап тору.

**ПОМЕ'ШИВАТЬ** II *несов.*— изгәләү, изгәләштерү; баскалау баскалаштыру; *помешивать тесто* — камыр изгәләү.

**ПОМЕ'ШКА** *ж. обл.*— к. помеха.

**ПОМЕ'ШКАТЬ** *сов. простореч.*— тоткарлану, соңга калу; *нельзя ли помешкать полчаса?* — берәр ярты сәгатькә соңга калырга ярамыймы?

**ПОМЕЩА'ТЬ** *несов.*— к. поместить.

**ПОМЕЩА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. поместиться; 2. *страд.* урнаштырылу.

**ПОМЕЩЕ'НИЕ** *ср.*— 1. *только ед.* (*действие*) к. поместить; 2. (*здание, комната*) бина, бүлмә.

**ПОМЕ'ЩИК** *м.*, **ПОМЕ'ЩИЦА** *ж.*— алпавыт, помещик.

**ПОМЕ'ЩИЧИЙ** — алпавыт...-ы, помещик...-ы, помещиклар...-ы, алпавытлар...-ы; *помещичьи земли* — алпавыт җирләре.

**ПОМИГА'ТЬ** *сов.*— 1. бераз күз кыскалау, күз кыскалап алу; 2. леп-леп итеп тору; *лампа помигала и потухла* — лампа леп-леп итеп торды да сүнде.

**ПОМИДО'Р** *м.*— помидор.

**ПОМИДО'РНЫЙ** — помидор...-ы; *помидорный сок* — помидор согы.

**ПОМИ'ЛОВАНИЕ** *ср. офиц. право* — гафу итү, кичерү; (югары власть органнары тарафыннан гаепне гафу итеп чыгарылган карар).

**ПОМИ'ЛОВАТЬ** *сов.*— 1. (*простить*) гафу итү, кичерү; 2. *офиц. право* (*отменить или ослабить наказание*) җәзаны җиңеләйтү яки юкка чыгару.

**ПОМИ'ЛУЙ, ПОМИ'ЛУЙТЕ** *пов. накл.*— тукта(гыз) әле, нишләп алай булсын ди, кара(гыз) әле; *помилуй, что ты делаешь* — тукта әле, нәрсә эшлисең син.

**ПОМИЛОСЕ'РДСТВОВАТЬ** *сов. книжс.*— шәфкать күрсәтү, мәрхәмәт итү (бераз). ◇ **Помилосердствуйте** — туктагыз әле, карагыз әле.

**ПОМИ'МО** *предлог с род. пад.*—...-дан башка,...-дан узып, исәпләшмичә, карамастан; *помимо нас* — бездән башка; *помимо его желания* — аның теләгенә карамастан.

**ПОМИ'Н** *м. простореч. церк.*— искә төшерү, хәтергә алу. ◇ **И помину нет** *разг.*— искә дә төшермиләр, телгә дә алмыйлар. **Лёгок на помине** *разг.*— гомерең озын булыр, сине генә сөйләп тора идек; *А! Легка на помине! Где это вы пропадали?* (Тургенев) — Ә! гомерегез озын булыр, сезне генә сөйләп тора идек, кая югалып тордыгыз? **В помине нет** — булганы да юк.

**ПОМИНА'ЛЬНЫЙ** *рел.*— искә алу...-ы; *поминальные обряды* — искә алу йолалары (үлгән кешене).

**ПОМИНА'НЬЕ** *ср. рел.*—1. к. поминки; 2. *разг. церк.* чиркәүдә искә алып дога кылу исемлеге.

**ПОМИНА'ТЬ** *несов. разг.*—1. искә алу, искә төшерү, хәтергә алу; *не поминайте лихом* — начар сүз белән телгә алмагыз, яманлап искә алмагыз; 2. *рел.* үлгән кешене искә алып дога кылу яки хәер бирү; *поминать усопших* — үлгән кешеләрне искә алып дога кылу. ◇ **Поминай, как звали** — к. звать.

**ПОМИНА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— искә алыну.

**ПОМИ'НКА** I *ж. мн.* нет — к. помяться 1.

**ПОМИ'НКА** II *ж. устар.*— бүләк (истәлек өчен бирелә торган бүләк).

**ПОМИ'НКИ** *ед.* нет —1. *рел.* атап искә алу (үлгән кешене искә алу мәҗлесе); *справить поминки по ком-н.*— кемне дә булса атап искә алу мәҗлесен үткәрү; 2. *перен. разг.* тантаналы рәвештә искә алу (үлгән кешене).

**ПОМИ'НОК** *м. устар.*— к. поминка II.

**ПОМИНУ'ТНО** — бик еш, минут саен, өзлексез.

**ПОМИНУ'ТНЫЙ** —1. минут саен булып тора торган; 2. *перен.* бик еш булып тора торган, һәрвакыт булып тора торган, өзлексез; 3. минут исәбеннән; *поминутная плата за междугородные телефонные переговоры* — шәһәрара телефонда сөйләшкән өчен минут исәбеннән түләү.

**ПОМИРА'ТЬ** *несов. просторен.*— үлү. ◇ **Помирать со смеху** *разг.*— егылганчы көлү, көлеп хәлдән таю, эче катып көлү, үлә язып көлү.

**ПОМИРИ'ТЬ** *сов.*— к. мирить.

**ПОМИРИ'ТЬСЯ** *сов.*—1. к. мириться; 2. к. примириться.

**ПО'МНИТСЯ** *вводн. слово* — хәтеремдә, хәтерлим; *помнится, он тогда же уехал* — хәтеремдә, ул шул вакытта ук китеп барды.

**ПО'МНИТЬ** *несов.*— истә тоту, хәтердә тоту, хәтерләү, онытмау; *всю жизнь буду помнить* — гомер буе истә тотармын. ◇ **Помнить себя** *книж.*— үзеңне хәтерләү; *я помню себя ребёнком* — мин үземне балачагымнан хәтерлим. **Не помнить себя** *книж.*— үзен-үзе белмәү, дөньясын оныту; *не помнить себя от радости* — шатлыктан үзен-үзе белмәү.

**ПОМНИ'ТЬ** *сов. книж. устар.*— явыз ният тоту, усал уйда булу.

**ПО'МНИТЬСЯ** *несов.*—1. онытылмау, истә калу, хәтердә калу; *такие дела долго будут помниться* — андый эшләр озак онытылмаслар.

**ПОМНО'ГУ** *нареч. разг.*—1. бик күп, күпләп, күп-күп итеп; *съедал помногу каши* — бик күп ботка ашап бетерә торган иде; 2. озак-озак; *мы помногу беседовали с ним* — без аның белән озак-озак сөйләшә идек.

**ПОМНОЖА'ТЬ** *несов.* — к. помножить.

**ПОМНОЖА'ТЬСЯ** *несов.*—1. к. помножиться; 2. *страд.* кабатлану, тапкырлану.

**ПОМНО'ЖИТЬ** *сов. мат.*— кабатлау, тапкырлау.

**ПОМНО'ЖИТЬСЯ** *сов.*— кабатлану, тапкырлану.

**ПОМО'ГА** *ж. мн.* нет, *обл. устар.*— к. помощь.

**ПОМОГА'ТЬ** *несов.*— к. помочь.

**ПОМОЗГОВА'ТЬ** *сов. просторен. фам.*— уйлап карау, баш йөртеп карау; *мы ещё помозгуем об этом* — без бу турыда уйлап карарбыз әле.

**ПОМО'И** *ед.* нет — юынтык су, шакшы су, пычрак су. ◇ **Обливать помоями** *разг. перен.*— кеше өстенә пычрак ташлау, бер кеше турында гайбәт сөйләү, яла ягу.

**ПОМО'ЙКА** *ж. разг.*— помойка, чүп-чар чокыры (чүп-чар, пычрак су түгә торган чокыр).

**ПОМО'ЙНИК** *м. обл.*— юынтык су чиләге.

**ПОМО'ЙНЫЙ:** **помойная яма** — чүп-чар, пычрак су түгә торган чокыр; *помойное ведро* — пычрак су чиләге.

**ПОМОКА'ТЬ** — к. помакать.

**ПОМО'КНУТЬ** *сов.*—1. чылану; *помокнешь ты сегодня в дороге* — бүген юлда син чыланырсың инде; 2. суда яту, җебү; *пусть солёная рыба помокнет дня два* — тозлы балык бер-ике көн суда ятсын.

**ПОМО'Л** *м. мн.* нет, *с.-х.*— он тарту, тарттырылу, тартылу; *мука мелкого помола* — вак тарттырылган он.

**ПОМО'ЛВИТЬ** *сов. устар.*— кыз яраштыру, ярәшү; вәгъдәләшү, сүз куешу (өйләнү, кияүгә чыгу турында).

**ПОМО'ЛВКА** *ж. устар.*— кыз ярәшү, вәгъдәләшү, сүз куешу (өйләнү, кияүгә чыгу турында).

**ПОМО'ЛЕЦ** *м. обл.*— к. помольщик.

**ПОМОЛИ'ТЬСЯ** *сов.*—1. к. молиться 1; 2. (*провести некоторое время в молитве*) гыйбадәт кылып алу, намаз укып алу.

**ПОМО'ЛКА** *ж. мн.* нет, *обл.*— к. помол.

**ПОМОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** *спец.*— помология...-ы; *помологическое общество* — помология җәмгыяте.

**ПОМОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет, *спец.*— помология (җиләк-җимеш үстерү теориясе).

**ПОМОЛОДЕ'ТЬ** *сов.*— яшәреп китү.

**ПОМОЛОТИ'ТЬ** *сов.*—1. ашлык сугып алу; 2. сугып бетерү; *весь хлеб помолотили* — барлык ашлыкны сугып бетердек.

**ПОМОЛО'ТЬ** *сов.*—1. (*закончить помол*) тарттырып бетерү (он турында); 2. (*провести некоторое время, меля*) тарттыру, тарттырып алу (он тарттыру).

**ПОМОЛЧА'ТЬ** *сов.*— эндәшми тору, бераз эндәшми тору, тынып тору, бераз тынып тору.

**ПОМО'ЛЬЩИК** *м.*— он тарттыручы, он тарттырырга килүче.

**ПОМОРГА'ТЬ** *сов.*— күз кыскалау.

**ПОМОРИ'ТЬ** *сов.*—1. бераз интектерү, бераз җәфалау; 2. кырып бетерү, үтереп бетерү.

**ПОМОРО'ЗИТЬ** *сов.*— өшетү, туңдыру, салкында тотып алу.

**ПОМОРОСИ'ТЬ** *сов.*— сибәләү, сибәләп алу; *поморосил дождь* — яңгыр сибәләп алды.

**ПОМОРО'ЧИТЬ** *сов. разг.*— (бераз вакыт) алдап йөртү, баш катырып йөртү.

**ПОМО'РЩИТЬ** *сов.*— к. морщить.

**ПОМО'РЩИТЬСЯ** *сов.*— чырай сыту; *он поморщился от боли* — авыртудан ул чыраен сытты.

**ПОМО'РЫ** *м.*— поморлар (Ак диңгез һәм Төньяк боз океаны буенда яшәүче төп рус халкы).

**ПОМО'РЬЕ** *ср.*— диңгез буе, диңгез кырые (төньякта); *Балтийское поморье*— Балтик диңгезе буе.

**ПОМОРЯ'НЕ** *м.*—1. диңгез буенда яшәүче халык; 2. *лингв. истор.* кашублар һәм словиннар (славян кабиләләренең көнбатыш чиктәге группасы).

**ПОМОРЯ'НКА** *ж.*— диңгез буенда яшәүче хатын-кыз.

**ПОМО'СТ** *м.*—1. күперчек, басма (күтәренке итеп такта түшәп ясалган мәйданчык); 2. эшафот (үлем җәзасын җиренә җиткерү урыны); 3. *обл.* басма (йорт җиткергәндә салына торган басмалар).

**ПОМОТА'ТЬ** I *сов.*—1. чорнап алу, бераз чорнап алу; *помотать нитки* — бераз җеп чорнап алу; 2. чайкап тору, селкеп тору; *помотал головой и пошёл* — башын селкеп торды да китте.

**ПОМОТА'ТЬ** II *сов. разг.*— бераз әрәмшәрәм итү, берникадәр туздыру, бераз туздыру; *помотать деньги* — бераз акча туздыру.

**ПОМОТА'ТЬСЯ** I *сов. разг.*— бераз селкенеп тору, бераз чайкалып тору.

**ПОМОТА'ТЬСЯ** II *сов. разг.*— (берникадәр вакыт) ил гизеп йөрү, бер җирдән икенче җиргә күчеп йөрү.

**ПО'МОХА** *ж. мн.* нет, *обл.*— 1. к. мга; 2. чык (ашлыкларга зарар китерә торган чык).

**ПОМОЧА'НИН** *м. устар.*— өмәгә катнашучы, өмәче.

**ПО'МОЧИ** *ед.* нет, *обл. спец.*— подтяжка (чалбарны тарттырып тора торган каеш яки тасма). ◇ **Быть или ходить на помочах** *разг. перен.*— кеше кубызына бию, кеше тезгенендә йөрү. **Водить на помочах** *разг. перен.* — үз кубызына биетү, тезгендә тоту.

**ПОМОЧИ'ТЬ** *сов.*— чылату, чылатып алу; *дождик нас помочил* — безне яңгыр чылатып алды.

**ПОМОЧИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— сию.

**ПО'МОЧЬ** *ж. мн.* нет —1. *устар. обл.* к. помощь; 2. өмә.

**ПОМО'ЧЬ** *сов.*— булышу, ярдәм итү, файдасы тию; *я помогу* — мин ярдәм итәрмен, мин булышырмын; *лекарство не помогло* — дару ярдәм итмәде, даруның файдасы тимәде.

**ПОМО'ЩНИК** *м.*, **ПОМО'ЩНИЦА** *ж.*— ярдәмче, булышчы.

**ПО'МОЩЬ** *ж. мн.* нет — ярдәм; *медицинская помощь* — медицина ярдәме; *скорая помощь* — ашыгыч ярдәм. ◇ **Не в помощь** — файдасызга, кирәксезгә. **С помощью** — ярдәме белән, ...ярдәмендә; *вода накачивается с помощью насоса* — су насос ярдәмендә суыртыла.

**ПО'МПА** I *ж. мн.* нет — помпа (кешеләрнең исен китәрү, хәйран калдыру өчен күрсәтелгән зиннәтлелек, үтә муллык, тантана); *встретить кого-н. с помпой* — берәр кешене помпа белән каршы алу.

**ПО'МПА** II *ж.*— насос.

**ПОМПАДУ'Р** *м. публ. ирон.*— помпадур (ни теләсә шуны эшли торган холыксыз администратор, кире беткән администратор).

**ПОМПАДУ'РСКИЙ** *публ. ирон.*— помпадур...-ы; помпадурлык...-ы; *помпадурские привычки* — помпадур гадәтләре.

**ПОМПАДУ'РСТВО** *ср. мн.* нет, *публ.*— помпадурлык сыйфаты.

**ПОМПЕ'ЗНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*—1. үтә зиннәтлелек, үтә купшылык; 2. тантаналылык.

**ПОМПЕ'ЗНЫЙ** *книж. устар.*— тантаналы; *помпезная встреча*—тантаналы каршылау; 2. үтә зиннәтле; *помпезная обстановка* — үтә зиннәтле йорт җиһазлары.

**ПОМПО'Н** *м.*— чук (хатын-кызлар яки балалар баш киемендә була торган шарсыман чук).

**ПОМРАЧА'ТЬ** *несов. книж. устар.*— к. помрачить.

**ПОМРАЧА'ТЬСЯ** *несов. книж. устар.*— к. омрачиться.

**ПОМРАЧЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— караңгылану; томанлану. ◇ **Помрачение сознания** — зиһен чуалу. **Помрачение зрения** —сукыраю. **Уму помрачение** *разг.*— искиткеч шәп; *рыбы были уму помрачение* — балыклар искиткеч шәп иде.

**ПОМРАЧИ'ТЬ** *сов. книж. устар.*— к. омрачить.

**ПОМРАЧИ'ТЬСЯ** *сов. книж. устар.*— к. омрачиться.

**ПОМРАЧНЕ'ТЬ** *сов.*— караңгыланып китү.

**ПОМСТИ'ТЬСЯ** *сов. обл.*— күзгә күренү; *это тебе помстилось* — бу күзеңә күренгәндер синең.

**ПОМУДРИ'ТЬ** *сов. разг. фам.*— бераз акыл сату, бераз акыл сатып алу.

**ПОМУДРОВА'ТЬ** *сов. простореч.*— к. помудрить.

**ПОМУ'ЖЕСТВОВАТЬ** *сов. разг.*— батырлык күрсәтү, батырлык күрсәтеп алу.

**ПОМУЗИЦИ'РОВАТЬ** *сов. разг.*— бераз уйнап алу (берәр төрле музыка коралында).

**ПОМУРА'ВИТЬ** *сов.*— глазурь (ялтыравык) йөгертеп алу, бераз глазурь йөгертеп алу (чүлмәккә).

**ПОМУРЛЫ'КАТЬ** *сов. разг.*— бераз мыраулап алу.

**ПОМУ'СЛИТЬ** *сов. разг.*— төкерекләп алу, бераз төкерекләп алу.

**ПОМУСО'ЛИТЬ** *сов.*— к. помуслить.

**ПОМУТИ'ТЬ** *сов.*—1. болганчыкландыру, бераз болганчыкландыру; *помутить воду* — суны болганчыкландыру; 2. *перен.* әйләндерү; *любовь помутила его голову* — мәхәббәт аның башын әйләндергән.

**ПОМУТИ'ТЬСЯ** *сов.*— болганчыклану, карацгылану; *помутилось синее море* — күк диңгез болганчыкланды; *помутилось в глазах* — күз аллары караңгыланды. ◇ **Сознание помутилось** — акылы томанланды, зиһене чуалды.

**ПОМУТНЕ'ТЬ** *сов.*— болганчыклану, куеру; *облака помутнели* — болытлар куерды.

**ПОМУТНИ'ТЬ** *сов. разг.*— болганчыкландыру.

**ПОМУ'ЧАТЬ** — к. помучить.

**ПОМУ'ЧАТЬСЯ** — к. помучиться.

**ПОМУ'ЧИВАТЬ** *несов. разг.*— бераз жәфалау, вакыт-вакыт жәфалау, интектереп алу.

**ПОМУ'ЧИТЬ** *сов. разг.*— газаплау, жәфалау; бераз интектерү, бераз газаплау, бераз жәфалау.

**ПОМУ'ЧИТЬСЯ** *сов. разг.*— (бераз вакыт) жәфалану, бераз интегү, бераз газаплану; *помучилась немного и умерла* — бераз жәфаланды да үлде.

**ПОМУШТРОВА'ТЬ** *сов.*— (берникадәр вакыт) муштровать итү, бераз муштровать итү.

**ПОМЧА'ТЬ** *сов.*—1. чаптырып алып китү; *лошади помчали* — атлар чаптырып алып киттеләр; 2. *простореч.* к. помчаться.

**ПОМЧА'ТЬСЯ** *сов.*— чабу, чабып китү, йөгереп китү, йөгерү; *собаки помчались за зайцем* — этләр куян артыннан чапты; *брат помчался за доктором* — агасы доктор чакырырга йөгерде; *один за другим помчались автомобили* — бер-бер артлы автомобильләр чаптылар.

**ПОМЫ'КАТЬ** *сов. обл. простореч.*— 1. бераз тетеп алу, бераз тәрәшләп алу; *помыкать лён* — бераз житен тәрәшләп алу; *помыкать шерсть* — бераз йон тетеп алу; 2. интегү, тазап чигү; *много горя я помыкал* — мин бик күп газап чиктем.

**ПОМЫКА'ТЬ** *несов.*— жәберләү, көн күрсәтмәү, жәфалау.

**ПОМЫ'КАТЬСЯ** *сов. разг. фам.*— күп интегеп йөрү, интегеп йөрү, каңгырып йөрү; *помыкаться по белу свету* — жир йөзендә күп интегеп йөрү.

**ПОМЫ'ЛИТЬ** *сов.*— бераз сабынлап алу; әзрәк сабынлап алу, бераз сабын сөртү.

**ПОМЫ'ЛИТЬСЯ** *сов. возв.*— бераз сабынлану, бераз сабын сөртенү.

**ПОМЫ'ЛКИ** *ед.* нет, *обл.*— сабынлы пычрак су.

**ПО'МЫСЕЛ** *м. книж.*— уй, теләк, фикер; *благие помыслы* — изге теләкләр.

**ПОМЫ'СЛИТЬ** *сов. разг.*— к. помышлять.

**ПОМЫТА'РИТЬ** *сов. разг.*— (бераз вакыт) интектерү, (бераз вакыт) йөдәтү, (бераз вакыт) азаплау, (бераз вакыт) жәфалау.

**ПОМЫТА'РИТЬСЯ** *сов. разг.*— (бераз вакыт) интегү, йөдәү, азаплану, жәфалану.

**ПОМЫ'ТЬ** *сов.*— юып алу; *помыть руки* — кулларны юып алу.

**ПОМЫ'ТЬСЯ** *сов.*— юынып алу; *надо помыться* — юынып алырга кирәк.

**ПОМЫЧА'ТЬ** *сов.*— мөгрәп кую, мөгрәп алу; *корова помычала* — сыер мөгрәп куйды.

**ПОМЫШЛЕ'НИЕ** *ср. книж. устар. разг. фам.*— уйлау, уй, фикер; *оставил всякое помышление об отъезде* — китү турында бөтенләй уйламый башлады.

**ПОМЫШЛЯ'ТЬ** *несов. разг.*— уйлау, фикерләү, хыяллану; *о женитьбе пока и не помышляй* — өйләнү турында хәзергә уйлама да (уйлап та карама).

**ПОМЯКА'ТЬ** *несов. разг.*— к. помякнуть.

**ПОМЯ'КЛЫЙ** *обл.*— шиңгән, ярым черек, пыжыган; *помяклая картошка* — шиңгән бәрәнге.

**ПОМЯ'КНУТЬ** *сов. разг.*—йомшару, жебү, изелү; *пряники помякли в дороге* — пряниклар юлда килгәндә изелгән.

**ПОМЯ'НУТЫЙ** — искә алынган, әйтеп кителгән, югарыда әйтелгән. ◇ **Не тем будь помянут** — алай начар итеп телгә аласы түгел иде.

**ПОМЯНУ'ТЬ** *сов.*— искә төшерү, телгә алу. ◇ **Помяни моё слово** — мин әйткәнне исеңдә тот, мин әйткән иде диярсең.

**ПОМЯ'ТЬ** *сов.*—1. таушалдыру; *помять костюм* — костюмны таушалдыру; 2. таптау; *помять траву* — үләнне таптау; 3. имгәтү; *медведь ему рёбра помял* — аю аның кабыргасын имгәткән; 4. *простореч. фам.* кыйнау, изү. ◇ **Помять бока** — дөмбәсләү, кабыргасын санау.

**ПОМЯ'ТЬСЯ** *сов.*—1. *(измяться)* таушалу, изелү, йомарлану; 2. *разг.* икеләнү, ыкмык итү; *он помялся, но потом согласился* — ул икеләнеп торды да соңыннан риза булды.

**ПОНАБИРА'ТЬ** *сов. разг.*— к. понабрать.

**ПОНАБРА'ТЬ** *сов. разг.*— жыю, төрле жирдән жыю, төрле жирдән жыеп алу; *понабрал повсюду работы* — төрле жирдән эш жыйган.

**ПОНАБРА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— жыелу; *желающих понабралось свыше ста человек* — теләүчеләр йөз кешедән артык жыелды. ◇ **Понабраться ума** — акыллылану, акыл жыю. **Понабраться знаний** — белем жыю, белем туплау.

**ПОНАБРОСА'ТЬ** *сов. разг.*— аз-мазлап ташлау, акрынлап ташлау; *понабросать мусору* — аз-мазлап чүп-чар ташлау.

**ПОНАВЕ'ДАТЬСЯ** *сов. разг. фам.*— к. наведаться.

**ПОНАВЕЗТИ'** *сов. разг.*— китереп тутыру; *понавезти на базар всяких овощей* — базарга һәртөрле яшелчәләр китереп тутыру.

**ПОНАВИДА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— к. навидаться.

**ПОНАГЛЕ'ТЬ** *сов.*— оятсызланып китү, оятсызрак булып китү.

**ПОНАГЛЯДЕ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— к. понасмотреться.

**ПОНАГНА'ТЬ** *сов. разг.*— 1. куып китерү (куып китереп бер урынга жыю); *понагнали много скота* — бик күп мал куып китергәннәр; 2. куып чыгару; *понагнать много смолы* — куып бик күп сумала чыгару.

**ПО-НАД** *предл. с твор. п. нар.-поэт.*— буенда, тирәсендә; *по-над Доном сады*

*цветут* — Дон буенда бакчалар чәчәк атып утыра.

**ПОНАДЕ'ЛАТЬ** *сов. разг.*— 1. әкренләп ясап кую, ясап кую; *понаделать коробочек* — бик күп итеп тартмалар ясап кую; 2. күп... тудыру, күп... чыгару; *понаделать хлопот* — күп мәшәкатьләр чыгару.

**ПОНАДЕ'ЯТЬСЯ** *сов. разг.* — ышану, өметләнеп тору, ышанып тору; *напрасно понадеялся на него* — юкка гына аңа ышанып тордым.

**ПОНА'ДОБИТЬСЯ** *сов. разг.*— кирәк булу; *ей понадобилась книга* — аңа китап кирәк булды.

**ПОНАЕ'ХАТЬ** *сов. разг.*— килеп тулу, күп булып килеп төшү; акрынлап килеп тулу; *понаехало много гостей* — бик күп кунаклар килеп тулды.

**ПОНАНЕСТИ'** *сов. разг.*— әкренләп китереп тутыру; *понанести всякой всячины* — әкренләп төрле юк-бар нәрсә китереп тутыру.

**ПОНАПРА'СНУ** *нареч. разг.*— юкка гына, бушка, тиккә, әрәмгә; *ходил понапрасну: не застал дома* — юкка гына бардым: өйдә юк иде.

**ПОНАСЛЫ'ШКЕ** *нареч. разг.*— ишетеп; *знать понаслышке* — ишетеп белү.

**ПОНАСМОТРЕ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— к. насмотреться 1.

**ПОНАСТРО'ИТЬ** *сов. разг.*— күп итеп салу, салып бетерү; *понастроили новых домов на окраинах* — шәһәр читләренә яңа йортлар салып бетергәннәр.

**ПОНАТАСКА'ТЬ** *сов. разг.*— 1. ташып тутыру; *понатаскать грязи в комнату* — бүлмәгә пычрак ташып тутырганнар; 2. аннан-моннан гына өйрәтү, аннан-моннан гына хәзерләү; *понатаскать его по математике* — аны аннан-моннан гына математикадан хәзерләү (мәсәлән, экзаменга).

**ПОНАТЕРЕ'ТЬСЯ** *сов. простореч.*— шомару; *понатёрся он около людей* — ул кеше арасында йөреп шомарган.

**ПОНАТЕ'ШИТЬСЯ** *сов. разг.*— к. натешиться.

**ПОНАТОРЕ'ТЬ** *сов. простореч.*— остару, өйрәнү, күнегү; *в стряпне понаторела* — пешеренергә өйрәнгән.

**ПОНАТУ'ЖИТЬСЯ** *сов. разг.*— көчәнү, бераз көчәнү, бераз көч кую.

**ПОНАЧА'ЛЬСТВОВАТЬ** *сов. разг.*— бераз начальник булып тору, бераз начальник булып алу.

**ПОНЁВА** *ж.*, **ПАНЁВА** *обл.*— юбка (1. өйдә сугылган йон тукымадан тегелгән юбка; 2. шундый тукыма).

**ПОНЕВО'ЛЕ** *нареч.*— ирексездән, ихтыярсыз, теләсәң-теләмәсәң дә, мәҗбүри; *поневоле пойдёшь* — теләсәң-теләмәсәң дә барырсың.

**ПОНЕВО'ЛИТЬ** *сов. простореч. устар.*— мәҗбүр итү, кушу, ирексезләп кушу.

**ПОНЕДЕ'ЛЬНИК** *м.*— дүшәмбе көн.

**ПОНЕДЕ'ЛЬНИЧНЫЙ** *устар.*— дүшәмбе көнге; *понедельничный номер газеты* — газетаның дүшәмбе көнге номеры.

**ПОНЕДЕ'ЛЬНО** *нареч.*— атналап; *работает понедельно* — атналап эшли.

**ПОНЕДЕ'ЛЬНЫЙ** — атналап..., атналык, атна саен...-а торган; *понедельная оплата* — атналап түләү; *понедельный график* — атналык график.

**ПОНЕ'ЖЕ** *союз старин. канц.*— чөнки.

**ПОНЕ'ЖИТЬ** *сов.*— иркәләү, бераз иркәләү, бераз иркәләп алу.

**ПОНЕ'ЖИТЬСЯ** *сов.*— иркәләнү (бераз), иркәләнеп алу, назланып алу; *любил утром понежиться в постели* — иртән түшәктә иркәләнеп ятырга ярата иде.

**ПОНЕ'ЖНИЧАТЬ** *сов. разг.*— бераз иркәләнеп алу, бераз назланып алу.

**ПОНЕМНО'ГУ** *нареч.*— 1. азлап-азлап, азлап кына; *он ест понемногу* — ул азлап-азлап ашый; 2. акрынлап; *больной начал понемногу поправляться* — авыру акрынлап терелә башлады. ◇ **Как поживаете?— Понемногу.**— Хәлләр ничек?— Бер көйгә.

**ПОНЕМНО'ЖКУ** *нареч. разг. фам.*— к. понемногу.

**ПОНЕСТИ'** *сов.*—1. күтәреп алып китү, күтәреп алып кайтып китү; *мать понесла ребёнка домой* — ана баласын күтәреп өйгә алып кайтып китте; 2. күтәреп бару; *чемодан тяжёлый, давай я немного понесу* — чемодан авыр, китер, мин бераз күтәреп барыйм; 3. *книж. офиц. устар.* башкару, үтәү; *понести много трудов* — бик күп эш башкару; 4. *перен. книж. офиц.* баштан кичерү, күрү; *понести наказание* — җәзасын күрү; *понести тяжёлую утрату* — зур югалтуны баштан кичерү; 5. *простореч. обл.* (*забеременеть*) балага узу, йөккә узу, корсакка калу; 6. (*о лошадях*) элдереп алып китү, томырылып чабып китү; *лошади понесли* — атлар элдереп алып китте; 7. *только 3 л.* или *безл.* өрү, исү, өрә башлау, исә башлау; *из окна понесло холодом* — тәрәзәдән салкын өрә башлады. ◇ **Куда тебя нелёгкая понесла?** — кай җәһәннәмгә киттең инде; ни шайтаныма анда барасың? **Понести ахинею, понести околесную** — юк-барны сөйли башлау, ахмак сүз сөйли башлау. **Понесло табаком** — тәмәке исе килә башлады. **Опять понёс, не слушайте его** — тагын тузга язмаганны сөйли башлады, тыңламагыз аны.

**ПОНЕСТИ'СЬ** *сов.*— чабып китү; *лошади понеслись* — атлар чабып китте.

**ПО'НИ** *нескл. м.*— пони (вак токымлы ат).

**ПОНИЖА'ТЬ** *несов.*— к. понизить.

**ПОНИЖА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. понизиться; 2. *страд.* киметелү, төшерелү, түбәнәйтелү, түбән төшерелү.

**ПОНИЖЕ'НИЕ** *ср.*— к. понизить и понизиться.

**ПОНИЗА'ТЬ** *сов.*— бераз җепкә тезү, җепкә тезеп бераз вакыт үткәрү.

**ПОНИЗИ'ТЕЛЬНЫЙ** *спец.*— электр тогын киметә торган; *понизительная подстанция* — электр тогын киметә торган подстанция.

**ПОНИ'ЗИТЬ** *сов.*— 1. түбәнәйтү; *пони-*

*зить забор* — койманы түбәнәйтү; 2. киметү, төшерү; *понизить давление* — басымны киметү; *понизить цены* — бәяләрне төшерү; 3. түбәнәйтү, начарайту; *понизить качество продукции* — продукциянең сыйфатын начарайту. ◇ **Понизить голос** — тавышны баса төшү, тавышны кыса төшү, шыпыртрак сөйләшә башлау. **Понизить по службе** — хезмәттә түбән урынга төшерү, кучерү.

**ПОНИ'ЗИТЬСЯ** *сов.* — түбәнәю; төшү, киму; *температура понизилась* — температура төште.

**ПОНИЗО'ВЩИНА** *ж. мн.* нет, *собир. простореч. устар.* — бурлаклар (елгаларның түбәнге агымында, елга тамагы тирәсендә шөгыльләнүче бурлаклар).

**ПОНИЗО'ВЫЙ** — елгаларның түбәнге агымындагы, елгалар тамагындагы...; *понизовые города* — елгалар тамагындагы шәһәрләр.

**ПОНИЗО'ВЬЕ** *ср.* — елгаларның түбәнге агымындагы урын, елга тамагындагы урын; *Волжское понизовье* — Иделнең түбәнге агымындагы урыннар.

**ПО'НИЗУ** *нареч.* — түбәннән, астан, җирдән, җир өстеннән; *дым стелется понизу* — төтен җир өстеннән җәелеп бара.

**ПОНИКА'ТЬ** *несов.*, **ПОНИ'КНУТЬ** *сов.* — к. никнуть.

**ПОНИМА'НИЕ** *ср. только ед.* — к. понимать I.

**ПОНИМА'ТЬ** I *несов.* — аңлау, төшенү. ◇ **Вот это я понимаю** — шәп тә соң инде. **Понимаете (ли), понимаешь (ли)** *разг. ввод. слово* — беләсезме, беләсеңме; *он, понимаете ли, очень помог бы нам* — беләсезме, ул безгә бик күп ярдәм итәр иде.

**ПОНИМА'ТЬ** II *несов. обл.* — су басу; *всю эту местность вода понимает* (Некрасов) — бу урыннарның бөтенесен дә су баса.

**ПОНИМА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — аңлану, аңлашылу; *эта фраза обычно понимается иначе* — бу фраза гадәттә башкача аңлашыла, бу фразаны гадәттә башкача аңлыйлар.

**ПОНИЩА'ТЬ** *сов. обл.* — к. нищать.

**ПОНОВЕ'ТЬ** *сов. разг.* — яңарып китү.

**ПОНОВИ'ТЬ** *сов.* — яңартып җибәрү; *поновить мебель лакировкой* — лаклап мебельне яңартып җибәрү.

**ПОНОВЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. поновить.

**ПОНОВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — яңартылу.

**ПОНОЖО'ВЩИК** *м. разг.* — сугышканда пычак кулланучы хулиган.

**ПОНОЖО'ВЩИНА** *ж. разг.* — пычак чәнчеп сугышу, чәнчешеп сугышу, пычакка пычак килеп сугышу.

**ПОНОМА'РИХА** и **ПОНОМА'РИЦА** *ж. разг. устар. обл.* — пономарь хатыны.

**ПОНОМА'РЬ** *м.* — пономарь (поп ярдәмчесе).

**ПОНО'С** *м.* — эч китү.

**ПОНОСИ'ТЕЛЬ** *м. книж. устар.* — хурлаучы, тиргәүче, яла ягучы.

**ПОНОСИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж. устар.* — мәсхәрә итә торган, мәсхәрәле, мәсхәрәләү...-ы; әшәке, хурлый торган; *поносительные слова* — мәсхәрә итә торган сүзләр, әшәке сүзләр.

**ПОНОСИ'ТЬ** I *несов. книж.* — тиргәү, хурлау, яманлау.

**ПОНОСИ'ТЬ** II *сов.* — 1. бераз күтәреп йөртү; *поносить ребёнка на руках* — баланы кулда бераз күтәреп йөртү; 2. кию; *пальто можно поносить ещё год* — пальтоны тагы бер ел кияргә мөмкин.

**ПОНОСИ'ТЬСЯ** I *несов. книж. страд.* — тиргәлү, хурлану.

**ПОНОСИ'ТЬСЯ** II *сов.* — киелү; *пальто ещё поносится год* — пальто тагы бер ел киелер әле.

**ПОНО'СКА** *ж. спец.* — поноска (1. өйрәтелгән этнең авызына каптырып алып бара яки алып кайта торган әйбер; 2. умарта кортларының билгеле бер вакыт эчендә җыйган балы).

**ПОНО'СНЫЙ** *книж. устар.* — хурлау...-ы тиргәү...-ы, яманлау...-ы; *поносные слова* — хурлау сүзләре.

**ПОНОШЕ'НИЕ** *ср. книж.* — 1. *(действие)* к. поносить 1; 2. *перен.* оят, хурлык, әдәм көлкесе; *поношение человеческое (устар.)* — әдәм көлкесе, әдәм хурлыгы.

**ПОНО'ШЕННЫЙ** — 1. *(о платье, обуви)* күп киелгән, тузган, искергән; *поношенное пальто* — күп киелгән пальто; 2. *перен.* азап-тузып йөрү аркасында йончыган, таушалган; *поношенный вид* — азып-тузып йөрү аркасында йончыган кыяфәт.

**ПОНРА'ВИТЬСЯ** *сов.* — күңелгә ошау, ошау; *с первого взгляда она мне понравилась* — беренче күрүдә ул минем күңелгә ошады; *эта картина мне не понравилась* — бу картина миңа ошамады.

**ПО'НТЕР** *м.* — к. пойнтер.

**ПОНТО'Н** *м.* — понто́н (1. вакытлыча салынган күперне күтәреп тора торган яссы төпле көймә; 2. вакытлыча корылган йөзмә күпер; 3. *спец.* суга баткан әйберләрне күтәрү өчен кулланыла торган эче куыш әрҗә яки цилиндр; 4. *устар.* коралсызландырып хәрби төрмәгә әйләндерелгән судно).

**ПОНТОНЁР** *м. воен.* — понтоннар төзүче гаскәри.

**ПОНТО'ННЫЙ** — понтон...; *понтонный мост* — понтон күпер.

**ПОНУДИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж. устар.* — мәҗбүри; *понудительные меры* — мәҗбүри чаралар, мәҗбүр итә торган чаралар. ◇ **Понудительный залог** *грам.* — йөкләтү юнәлеше.

**ПОНУ'ДИТЬ** *сов.* — мәҗбүр итү, ирексезләп кушу, көчләп кушу.

**ПОНУЖДА'ТЬ** *несов. книж.* — к. понудить.

**ПОНУЖДЕ'НИЕ** *ср. книж.* — к. понудить.

**ПОНУ'КАТЬ** *сов.* — „ну, ну", „я, я" дип ашыктыру.

**ПОНУКА'ТЬ** *несов. разг.* — 1. „на-на" дип куу (атны); 2. *перен. разг.* „әле", „я әле", „тиз бул, тиз бул" дип ашыктыру.

**ПОНУ'РИВАТЬ** *несов. редко* — к. понурить.

**ПОНУ'РИТЬ** сов.: **понурить голову** — башны салындыру.

**ПОНУ'РИТЬСЯ** *сов.* — башны салындыру.

**ПОНУ'РЫЙ** — боек, күңелсез, кәефсез; *понурый взгляд* — боек караш.

**ПО'НЧИК** *м.* — пончик, сумса.

**ПОНЫ'НЕ** *нареч. книж. устар.* — бүгенгәчә, әле дә булса, моңача, хәзерге вакытка тикле, әлегә чаклы; *живёт поныне* — әлегә чаклы яши.

**ПОНЫРЯ'ТЬ** *сов. разг.* — бераз чуму, чумып алу; *понырять в речке* — бераз елгада чумып алу.

**ПОНЫ'ТЬ** *сов.* — 1. бераз сызлап алу; 2. *разг. пренебр.* бераз шыңшып алу, бераз зарланып алу.

**ПОНЮ'Х** *м. разг. устар.* — к. понюшка.

**ПОНЮ'ХАТЬ** *сов.* — иснәп карау, иснәп алу. ◇ **Не дать и понюхать** *разг.* — иснәтеп тә карамау.

**ПОНЮ'ШКА** *ж. разг.* — 1. бер чеметем тәмәке; 2. (*действие*) к. понюхать. ◇ **Ни за понюшку табаку** *(погов.)* — бер дә юкка, файдасызга

**ПОНЯ'ВА** — к. панева.

**ПОНЯ'НЬЧИТЬ** *сов. разг.* — бераз бала карау, бераз бала карап тору.

**ПОНЯ'НЬЧИТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. бераз бала карап тору; 2. *перен.* маташу, әвәрә булу; *довольно мы с ним понянчились, пусть теперь работает сам* — без аның белән житәрлек маташтык инде, хәзер үзе эшләсен.

**ПОНЯ'ТИЕ** *ср.* — 1. *науч.* аң, төшенчә; *противоположные понятия* — капма-каршы төшенчәләр; 2. *только ед. разг.* белү, аңлау; *когда он приезжает?— понятия не имею* — кайчан килә ул?— һич белмим; *надо тоже понятие иметь!* — аңларга кирәк бит! 3. *просторeч.* аң; *человек с понятием* — аңлы кеше; 4. *устар. (способность понимания)* аңлау сәләте. ◇ **Дать понятие** — таныштыру. **Здравые понятия** — аек төшенчәләр.

**ПОНЯ'ТЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — зирәклек, аңлаучан булу; тиз аңлаучанлык; *понятливость ребёнка всех удивляла* — баланың аңлаучан булуына бөтен кешенең исе китә иде.

**ПОНЯ'ТЛИВЫЙ** — зирәк, тиз аңлый торган, тиз төшенә торган; *понятливый ученик* — тиз аңлый торган укучы.

**ПОНЯ'ТНО** *нареч.* — 1. аңлаешлы; *понятно говорить* — аңлаешлы сөйләү; 2. *в знач. ввод. сл.* билгеле, әлбәттә; *я, понятно, приду* — мин, әлбәттә, килермен.

**ПОНЯ'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — аңлаешлылык; *понятность вопроса* — мәсьәләнең аңлаешлылыгы.

**ПОНЯ'ТНЫЙ** — 1. аңлаешлы, ачык, аңларлык, төшенерлек; *понятное выражение* — аңлаешлы әйтелмә; 2. төпле, нигезле; *вполне понятное требование* — бик нигезле таләп; 3. *просторeч.* аңлаучан, тиз төшенүчән, тиз аңлый торган, тиз төшенә торган; *понятный парень* — тиз аңлый торган егет. ◇ **Понятное дело** *в знач. вводн. слова разг.* — әлбәттә, билгеле, үзеннән-үзе аңлашыла.

**ПОНЯТО'Й** *м. офиц.* — пүнәтәй, таныкк (тентү вакытында таныкк итеп чакырылган күрше-күлән).

**ПОНЯ'ТЬ** I *сов.* — аңлау, төшенү; *плохо понял статью* — мәкаләне начар аңлаган. ◇ **Дать понять** — сиздереп кую, тел төбе кая барганын сиздереп кую.

**ПОНЯ'ТЬ** II *сов. обл.* — су басу; *калину с малиною вода поняла* — балан белән кура җиләген су баскан.

**ПООБВЫ'КНУТЬ** *сов. просторeч.* — акрынлап күнегү.

**ПООБЕ'ДАТЬ** *сов.* — төшке ашны ашап алу, обед ашап алу.

**ПООБЕЩА'ТЬ** *сов. разг.* — к. обещать.

**ПООБЖИ'ТЬСЯ** *сов. просторeч.* — акрынлап өйрәнү, акрынлап күнегү, акрынлап ияләшү (яңа өйгә, яңа урынга).

**ПООБНОСИ'ТЬ** *сов. просторeч.* — туздырып бетерү.

**ПООБНОСИ'ТЬСЯ** *сов. просторeч.* — кием-салым тузу, кием-салым тузып бетү.

**ПООБОЖДА'ТЬ** *сов. разг.* — бераз көтү, бераз көтеп тору; *придётся пообождать* — бераз көтеп торырга туры килер.

**ПООБСО'ХНУТЬ** *сов. разг.* — бераз кибү, акрынлап кибү; *одежда пообсохла* — кием акрынлап кипте.

**ПООБЫ'КНУТЬ** *сов.* — к. пообвыкнуть.

**ПОО'ДАЛЬ** *нареч.* — арырак, тегендәрәк; *поодаль есть дорожка* — арырак юл бар.

**ПООДИНО'ЧКЕ** *нар.* — берәмләп.

**ПООКТЯ'БРЬСКИЙ** *нов.* — Октябрь революциясеннән соңгы; *пооктябрьская литература* — Октябрь революциясеннән соңгы әдәбият.

**ПООСМОТРЕ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. як-якка каранып алу; *он поосмотрелся* — ул як-якка каранып алды; 2. *перен. (немного свыкнуться с окружающим)* бераз ияләшү, бераз күнегү.

**ПООСТРИ'ТЬ** I *сов.* — бераз үткенләп алу, үткенләп алу, бераз очлап алу; *поострить нож* — пычакны бераз үткенләп алу.

**ПООСТРИ'ТЬ** II *сов. разг.* — үткен сүзләр әйткәләп алу, үткен сүзләр әйтеп алу, төрттереп әйтеп кую; *ему хочется поострить* — аның үткен сүзләр әйтәсе килә.

**ПООТВЫ'КНУТЬ** *сов. разг.* — акрынлап бизү, бара-бара күңеле кайту.

**ПОО'ХАТЬ** *сов. разг.* — ухылдап алу, бераз ухылдап алу, ах-вах итеп алу.

**ПООХО'ТИТЬСЯ** *сов.* — бераз ауда йөрү; *уехал поохотиться* — бераз ауда йөрергә китте.

**ПООЧЕРЁДНЫЙ** — бер-бер артлы, чиратлашып эшләнгән, чиратлап, чиратлашып; *поочерёдное дежурство* — чиратлап дежурить итү.

**ПООЩРЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *(действие)* к. поощрить; 2. *(награда)* бүләк.

**ПООЩРИ'ТЕЛЬНЫЙ** — күңел күтәрә торган, дәртләндерә торган, хуплый торган, мактый торган; *поощрительный тон* — күңел күтәрә торган тон.

**ПООЩРИ'ТЬ** *сов.*— 1. күңелен күтәрү, дәртләндерү; *поощрить хорошего рабочего* — яхшы эшченең күңелен күтәрү; 2. юл кую; *поощрить лень* — ялкаулыкка юл кую.

**ПООЩРЯ'ТЬ** *несов.*— к. поощрить.

**ПООЩРЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— күңел күтәрелү, дәртләндерелү, юл куелу.

**ПОП** *м.*— поп. ◇ **Поставить на попа** — бастырып кую; *поставить кирпич на попа* — кирпечне бастырып кую.

**ПОПАДА'НИЕ** *ср.*— к. попасть 1, попада́ть.

**ПОПА'ДАТЬ** *сов.*— 1. коелу, коелып төшү; *яблоки попадали с яблони* — алмагачтан алмалар коелып төште; 2. (бер-бер артлы) төшеп бетү; төшкәләп бетү; *книги попадали с полок* — киштәләрдән китаплар төшеп бетте; 3. егылу; *многие попадали в обморок* — күбесе һуштан язып егылды; 4. *(упасть много раз) разг.* берничә тапкыр егылу.

**ПОПАДА'ТЬ** *несов.*— к. попасть.

**ПОПАДА'ТЬСЯ** *несов.*— к. попасться.

**ПОПАДЬЯ'** *ж. разг.* — поп хатыны.

**ПОПА'ИВАТЬ** *несов. разг.*— азлап-азлап эчерү.

**ПОПА'ЛИВАТЬ** *несов. разг.*— 1. өткәләштерү, өткәләү; *попаливать курицу* — тавыкны өткәләү; 2. сирәк-мирәк аткалау; *попаливать из ружья* — сирәк-мирәк мылтык аткалау.

**ПОПАЛИ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. өтеп алу; *попалить курицу* — тавыкны өтеп алу; 2. *разг. (пострелять в течение некоторого времени)* бераз аткалау, бераз атып алу; 3. *устар.* яндыру, яндырып бетерү; *неприятель попалил много сёл* — дошман бик күп авылларны яндырды.

**ПОПА'РИТЬ** *сов.*— 1. бераз чабу; *попарить спину в бане* — мунчада арканы бераз чабу; 2. кыздыру; *попарить горшки в печке* — чүлмәкләрне мичтә кыздыру.

**ПОПАРИ'ТЬ** *сов.*— җилпенми очып алу, талпынмый очып алу; җилпенми очкалау, талпынмый очкалау.

**ПОПА'РИТЬСЯ** *сов.*— 1. чабыну; *попариться в бане* — мунча чабыну; 2. кызу, кызып кибү; *горшки попарились в печке* — чүлмәкләр мичтә кызып киптеләр.

**ПОПА'РНО** *нареч.*— икешәрләп, парлашып, пар-пар булып, куш-куш булып; *ученики шли попарно* — укучылар пар-пар булып баралар иде.

**ПОПАСТИ'** *сов.*— бераз көтү көтү, көтүдә йөртү, көтү; *попасти коров* — бераз сыер көтү.

**ПОПАСТИ'СЬ** *сов.*—көтүдә йөрү; *коровы попаслись до полудня* — сыерлар төшкә кадәр көтүдә йөрделәр.

**ПОПА'СТЬ** *сов.*— 1. тидерү, тию, төшү; *пуля попала в ногу* — пуля аякка тиде; *снаряд попал в блиндаж* — снаряд блиндажга төште; 2. кертү; *попасть ниткой в ушко иголки* — җепне энә күзенә кертү; 3. ялгыш басу, ялгыш тыгылу; *попасть в канаву ногой* — аяк белән ялгыш канауга басу; *попасть рукой в суп* — кул белән ялгыш ашка тыгылу; 4. очрату, табу, көтмәгәндә барып чыгу; *попасть на дорогу* — көтмәгәндә юлга барып чыгу; *наконец, я попал на хорошего помощника* — ахыр чиктә мин үземә яхшы ярдәмче таптым; 5. эләгү, керү; *как ты сюда попал?* — син монда ничек кердең? 6. барып житү, килеп җитү, кайтып җитү; *мы попали домой к вечеру* — без өйгә кичкә таба гына кайтып җиттек; *не попал во время на работу* — вакытында эшкә барып җитә алмадым; 7. эләгү, төшү, очрау; *попасть в плен* — пленга төшү; *попасть под суд* — судка эләгү; *тебе за это попадёт* — сиңа моның өчен эләгер; *попасть в беду* — бәлагә эләгү; 8. керү; *попасть в техникум* — техникумга керү; 9. ... исеме алу, аталу; *попасть в сплетники* — гайбәтче исеме алу, гайбәтче дип аталу; 10. *простореч.* очрау; *он мне попал навстречу* — ул миңа каршы очрады. ◇ **Где попало** — теләсә кайда, кая җитте анда. **Как попало** — теләсә ничек, ничек туры килсә шулай. **Чем попало** — ни туры килсә шуның белән. **Как попало, как ни попало** — ничек җитте шулай, ничек туры килсә шулай. **Попасть в просак** — к. просак. **Попасть на зубок** — к. зубок. **Попасть под руку** — кул астына эләгү. **Попасть в точку** — өстенә басу. **Бить чем (ни) попадя** *простореч.*— теләсә нәрсә белән сугу, ни туры килсә шуның белән сугу.

**ПОПА'СТЬСЯ** *сов.*— 1. эләгү, төшү; *попасться в капкан* — капкынга эләгү; *попасться в плен* — пленга төшү; 2. эләгү, тотылу; *попасться в воровстве* — урлашып тотылу; 3. *разг.* очрау; *попался мне один рыбак* — миңа бер балыкчы очрады. ◇ **Попасться на глаза** — күзгә чагылу, күзгә чалыну. **Попасться под руку** — кул астына эләгү. **Первый попавшийся** — чит кеше, таныш булмаган очраклы кеше; *рассказывать первому попавшемуся* — таныш булмаган очраклы кешегә сөйләп бирү.

**ПОПА'ХИВАТЬ** I *несов. разг.*— ис килү, бераз исләнгән булу; *рыба попахивает* — балыктан ис килә, балык бераз исләнгән.

**ПОПА'ХИВАТЬ** II *несов. разг.* — җил бәреп тору, җил искәләп тору.

**ПОПЕВА'ТЬ** *несов. разг.*— җырлаштыргалау, җырлап алгалау, акрын гына җырлау.

**ПОПЁННЫЙ** *спец.* — төп башыннан; *попённая оплата* — төп башыннан түләү (агач кискән өчен).

**ПОПЕНЯ'ТЬ** *сов. разг.*— к. пенять.

**ПОПЕРВОНАЧА'ЛУ** *нареч. простореч.*— башта, иң башта ук, әүвәле.

**ПОПЕРЁК** *предлог с род. п.*— 1. аркылы; *поставить телегу поперёк улицы* — арбаны урамга аркылы кую; 2. *разг. нареч.* аркылыга; *пилить бревно поперёк* — бүрәнәне аркылыга кисү; 3. *перен.* каршы, кирегә, юри, уч итеп; *поперёк говорить* — кирегә сөйләү. ◇ **Поперёк горла (стать)** — тамакка таш булып утыру. **Вдоль и поперёк** — к. вдоль.

**ПОПЕРЕМЕ'ННО** *нареч.*— алмашлап, алмаш-тилмәш, бер-бер артлы; *читать вслух попеременно* — алмашлап кычкырып уку.

**ПОПЕРЕ'ТЬ** *сов. простореч. вульг.*— 1. юнәлү, китү, китеп бару; *ты куда попёр,*

*на ночь глядя* — төнгә каршы син кая китеп барасың; 2. куып чыгару; *его оттуда попёрли* — аны аннан куып чыгарганнар; 3. күтәреп алып китү; *попёр на себе корзину* — кәрзинне күтәреп алып китте.

**ПОПЕРЕ'ТЬСЯ** *сов. обл. простореч.*— китеп бару; *куда ты попёрся в таком виде* — бу килеш кая китеп барасың син.

**ПОПЕРЕ'ЧИНА** *ж.*— аркылы борыс.

**ПОПЕРЕ'ЧИТЬ** *сов. разг.*— каршы килү, киреләнү, ризасызлык белдерү.

**ПОПЕРЕ'ЧНИК** *м.*— 1. *тех.* диаметр; 2. *спец.* к. поперечина; 3. аркалык; 4. *обл. (тот, кто любит перечить)* кире кеше, үҗәт.

**ПОПЕРЕ'ЧНЫЙ** — аркылы; *поперечная пила* — аркылы пычкы. ◇ **Встречный и поперечный** — һәрбер очраган кеше. **Поперечная мука́** *спец.*— иләнмәгән арыш оны.

**ПО'ПЕРЕЧЬ** *нареч. обл.*— поперёк.

**ПОПЕРХНУ'ТЬСЯ** *сов.*— чәчәү.

**ПОПЕ'РЧИТЬ** *сов. разг.*— борычлау, бераз борыч сибү.

**ПОПЕ'СТОВАТЬ** *сов.*— к. пестовать.

**ПОПЕ'ТЬ** *сов.*— бераз җырлап алу.

**ПОПЕЧА'ЛИТЬСЯ** *сов.*— бераз кайгырып алу, берникадәр кайгыру, бераз кайгыру, бераз хәсрәтләнү.

**ПОПЕЧЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— 1. кайгырту, карау, яклау; *общество попечения о престарелых* — картларны кайгырту җәмгыяте; 2. тәрбия; *оставить на попечение родителей* — ата-анасы тәрбиясенә калдыру. ◇ **Отложить попечение** *разг.*— уйламый башлау, кайгыртмый башлау.

**ПОПЕЧИ'ТЕЛЬ** *м. офиц.*— 1. кайгыртучы, караучы, тәрбия итүче (балигъ булмаган балаларны һ. б. карау өчен опека оешмалары тарафыннан билгеләнгән кеше); 2. попечитель (революциягә кадәр Россиядә кайбер учреждение башлыкларына биреләторган звание).

**ПОПЕЧИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж. офиц.*— к. попечитель.

**ПОПЕЧИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. *офиц.* попечительләр...-ы; *попечительский совет* — попечительләр советы; 2. *устар.* кайгыртучан; *попечительный друг* — кайгыртучан дус.

**ПОПЕЧИ'ТЕЛЬСТВО** *ср. офиц.*— 1. опека, попечительство (балигъ булмаган балаларга һәм ярдәмгә мохтаҗ кешеләргә ярдәм күрсәтү чаралары системасы); 2. *дорев.* попечительство, җәмгыяте хәйрия (фәкыйрьләргә, ятимнәргә ярдәм күрсәтү өчен оештырылган ирекле оешма); 3. *(должность попечителя)* попечительлек вазыйфасы.

**ПОПЕЧИ'ТЕЛЬСТВОВАТЬ** *несов. офиц.*— попечительлек вазыйфасын үтәү, попечитель булып тору.

**ПОПЕ'ЧЬ** *сов.*— 1. пешерү, пешереп алу; *попечь блины* — белен пешереп алу; 2. *разг.* кыздыру, шактый кыздыру; *солнце попекло нас в поле* — басуда кояш безне шактый кыздырды.

**ПОПЕ'ЧЬСЯ** *сов.*— 1. пешә төшү, пешеп җитә төшү; *пусть ещё попекутся булки в печи* — булкалар мичтә пешә төшсеннәр әле; 2. *разг.* бераз кызыну; *попеклись в поле на солнце* — басуда бераз кояшта кызындык; 3. *разг.* кайгырту; *попекись о родных* — туганнарың турында кайгырт.

**ПОПИВА'ТЬ** *несов. разг. фам.*— эчкәләштерү, эчкәләү, аз-маз эчкәләү. ◇ **Сидит, чаёк попивает** — рәхәтләнеп чәй эчеп утыра.

**ПОПИЛИ'ТЬ** *сов.*— 1. кискәләп алу; *попилим немного* — бераз кискәләп алыйк әле; 2. *перен.* шелтәләп алу; *старуха попилила внука за шалость* — карчык оныгын шаярган өчен шелтәләп алды.

**ПОПИРА'ТЕЛЬ** *м. книж. устар.*— санга сукмаучы, хисаплашмаучы, аяк астына салып таптаучы; *попиратель чужих прав* — башкаларның хокукларын аяк астына салып таптаучы.

**ПОПИРА'ТЬ** *несов. книж. ритор.*— 1. таптау; *попирать вражескую землю* — дошман җирен таптау; 2. *перен.* кимсетү, санга санамау, исәпкә алмау, тупас рәвештә бозу; *попирать чьи-н. права* — берәр кешенең хокукларын санга санамау, берәр кешенең хокукларын тупас рәвештә бозу.

**ПОПИРОВА'ТЬ** *сов.*— сыйланып алу, сыйланып күңел ачып алу.

**ПОПИСА'ТЬ** *сов.*— язу, язып алу; *пописать с полчаса* — бер ярты сәгать язу.

**ПОПИ'СКИВАТЬ** *несов.*— чыелдап-чыелдап кую.

**ПОПИ'СЫВАТЬ** *несов. разг.*— язгалаштыру, вакыт-вакыт язгалау; *он пописывает статейки* — ул мәкаләләр язгалаштыра.

**ПОПИ'ТЬ** *сов. разг.*— эчү, бераз эчү, әзрәк эчү; *попить воды* — әзрәк су эчү.

**ПО'ПКА** *м. разг. ласкат.*— к. попугай.

**ПОПЛА'ВАТЬ** *сов.*— бераз йөзеп алу, бераз йөзү.

**ПОПЛАВО'К** *м.*— 1. калкавыч; 2. поплавок (а. *мор.* фарватерны күрсәтү өчен якорьга бәйләп су өстенә куелган билге; б. *спец.* гаскәрләрне су аркылы чыгару өчен кулланыла торган, эченә һава тутырылган резина капчык; в. *авиац.* судан күтәрелеп китү өчен самолётның тәгәрмәчләре урынына ясалган көймәсыман җайланма; г. *разг.* махсус баржада яки яр кырыенда субайлар өстенә корылган ресторан).

**ПОПЛА'КАТЬ** *сов.*— бераз елау, бераз елап алу; *вечером она поплакала* — кичен ул бераз елап алды.

**ПОПЛА'КАТЬСЯ** *сов.*— 1. к. плакаться; 2. бераз зарланып алу, бераз зарлану.

**ПОПЛАТИ'ТЬСЯ** *сов.*— җәзасын күрү, кирәген алу; *поплатиться за ошибку* — хата өчен кирәген алу, җәза күрү. ◇ **Поплатиться здоровьем** — сәламәтлеген югалту. **Поплатиться головой** — башын кую, җанын бирү.

**ПОПЛЕВА'ТЬ** *сов. разг.*— төкергәләп алу; *поплевал на руки и взялся за работу* — кулларына төкергәләп алды да эшенә тотынды.

**ПОПЛЁВЫВАТЬ** *несов. разг.*— вакыт-вакыт төкереп алу, вакыт-вакыт төкереп ташлау, төкергәләү.

**ПОПЛЕСКА'ТЬ** *сов. обл.*— сибеп алу; бераз сибү; *поплескать на голову водой из ведра* — чиләк белән башка бераз су сибү.

**ПОПЛЕСКА'ТЬСЯ** *сов.*— чупырдап коену, коену; *поплескаться в ванне* — ваннада коену.

**ПОПЛЁСКИВАТЬ** *несов. разг.*— вакыт-вакыт сибеп кую, сирәк-мирәк чәчрәтеп кую; *поплёскивать водой из ковша* — вакыт-вакыт чүмеч белән су сибеп кую.

**ПОПЛЕСТИ'** *сов.*— бераз үреп алу, берникадәр вакыт үрү.

**ПОПЛЕСТИ'СЬ** *сов. разг.*— акрын гына атлап китү, чак-чак кына атлап китеп бару.

**ПОПЛИ'Н** *м.*— поплин (вак сырлы ефәк тукыма).

**ПОПЛИ'НОВЫЙ** — поплин..., поплиннан тегелгән; *поплиновое платье* — поплиннан тегелгән күлмәк, поплин күлмәк.

**ПОПЛОТНЕ'ТЬ** *сов.*— тыгызлану, катылану, тыгызлана төшү, катылана төшү.

**ПОПЛУТА'ТЬ** *сов. разг.*— бераз вакыт адашып йөрү; *поплутать по лесу* — урманда адашып йөрү.

**ПОПЛЫ'ТЬ** *сов.*—1. йөзеп китү; *поплыть к берегу* — ярга таба йөзеп китү; 2. агып китү; *щепка поплыла* — йомычка агып китте; 3. ташып чыгу, ташып китү; *молоко поплыло* — сөт ташып чыкты. ◇ **Всё поплыло перед глазами** — күз алларым караңгыланып китте.

**ПОПЛЯСА'ТЬ** *сов. разг.*— биеп алу, бераз биеп алу. ◇ **Ты у меня попляшешь** *разг. фам.* — мин сине биетермен әле, мин сине кызган табага бастырырмын әле.

**ПОПЛЯ'СЫВАТЬ** *несов. разг.*— бию, биеп алгалау; *поплясывает иногда* — кайчакта биеп алгалый.

**ПОПО'ВИЧ** *м.*— поп малае.

**ПОПО'ВНА** *ж. разг.*— поп кызы.

**ПОПО'ВНИК** *м. бот.*— 1. к. пастернак; 2. балтырган үләне.

**ПОПО'ВЩИНА** *ж. мн.* нет, *пренебр.*— дини хорафатлар.

**ПОПОИ'ТЬ** *сов. простореч.*— эчерү, эчәргә бирү; *попоить ребёнка молоком* — балага сөт эчерү.

**ПОПО'ЙКА** *ж. разг.*— эчке мәҗлесе, эчү мәҗлесе.

**ПОПОЛА'М** *нареч.*— 1. урталай; *разрезать хлеб пополам* — икмәкне урталай кисү; 2. уртакка; *купить пополам* — уртакка сатып алу; 3. яртылаш; *молоко пополам с водой* — яртылаш су кушкан сөт. ◇ **С грехом пополам** — ничек кирәк алай, көч-хәл белән.

**ПОПОЛА'СКИВАТЬ** *несов. разг.*— сирәк-мирәк чайкау, чайкаштыргалау.

**ПОПО'ЛДНИЧАТЬ** *сов. обл.*— әбәт ашап алу.

**ПОПОЛЗНОВЕ'НИЕ** *ср. книж.*—уй, теләк, ният; *у него было поползновение уехать* — аның китәргә нияте бар иде.

**ПОПОЛЗТИ'** *сов.*— үрмәләп китү, шуышып китү.

**ПОПОЛНЕ'НИЕ** *ср.*—1. *только ед. (действие)* к. пополнить; 2. *воен.* пополнение (хәрби частьларны тулыландыру өчен җибәрелгән гаскәр); *на фронт прибыло пополнение* — фронтка пополнение килде; 3. к. пополнеть.

**ПОПОЛНЕ'ТЬ** *сов.*— калыная төшү, юаная төшү, симереп китү, калынаеп китү, юанаеп китү.

**ПОПО'ЛНИТЬ** *сов.*— арттыру, өстәү, тутыру, тулыландыру; *пополнить свои знания* — белемеңне арттыру.

**ПОПО'ЛНИТЬСЯ** *сов.*— арту, тулу, баю, тулылану; *состав служащих пополнился* — хезмәткәрләрнең составы артты; *библиотека пополнилась новыми книгами* — китапханә яңа китаплар белән тулыланды (китапханә яңа китаплар белән тулыландырылды).

**ПОПОЛНЯ'ТЬ** *несов.*— к. пополнить.

**ПОПОЛНЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. пополниться; 2. *страд.* тулыландырылу, тутырылу, өстәлү, арттырылу, баетылу.

**ПОПОЛОСКА'ТЬ** *сов. обл.*— бераз чайкау, бераз чайкап алу; *пополоскать бельё* — бераз кер чайкап алу.

**ПОПОЛОСКА'ТЬСЯ** *сов. обл.*— су чәчрәтешеп алу, чупырдашып алу; *дети пополоскались в ванне* — балалар ваннада су чәчрәтешеп алдылар.

**ПОПОЛО'ТЬ** *сов.*— утап алу, бераз утап алу; *пополол с полчаса* — бер ярты сәгать утап алды.

**ПОПОЛУ'ДНИ** *нареч.*— төштән соң, төш узгач.

**ПОПОЛУ'НОЧИ** *нареч.*— төн уртасыннан соң, ярты төн узгач.

**ПОПО'ЛЬЗОВАТЬ** *сов. устар.*— бераз дәвалап алу, дәвалау; *попользовать больного* — авыруны дәвалау.

**ПОПО'ЛЬЗОВАТЬСЯ** *сов.*— 1. бераз файдалану; *я немного попользовался его книгой* — аның китабы белән мин бераз файдаландым; 2. *устар.* (*полечиться*) дәвалану.

**ПОПО'МНИТЬ** *сов.*— 1. онытмау, искә алу; *попомнят моё добро* — минем яхшылыкны онытмаслар; 2. үчен алу; *я тебе это попомню* — мин синнән моның үчен алырмын әле. ◇ **Попомни моё слово!** — *разг.*— мин әйтте диярсең, күрерсең әле, мин әйткәнчә булыр.

**ПОПО'НА** *ж.*— ат япмасы (ат өстенә яба торган җәймә).

**ПОПО'РТИТЬ** *сов. разг.*— к. испортить.

**ПОПО'РТИТЬСЯ** *сов. разг.*— к. испортиться.

**ПОПОТЕ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. бераз тирләү; *больной ночью немного попотел* — авыру төнлә бераз тирләде; 2. *перен.* көч кую; көч салу, тырышу; *попотел над задачей* — мәсьәләне чишү өчен күп көч куйды.

**ПОПО'ТЧЕВАТЬ** *сов.*— 1. бераз сыйлау; 2. *перен. простореч. шутл.* көрәген бирү, кыйнау, сыйлау; сылау, ямау; *попотчевал его дубиной* — мин аны күсәк белән сыйладым.

**ПОПРАВЕ'ТЬ** *сов.*— к. праветь.

**ПОПРАВИ'МЫЙ** — төзәтелә алырлык, төзәтелерлек, төзәтеп була торган.

**ПОПРА'ВИТЬ** I *сов.*— 1. төзәтү; *поправить часы* — сәгатьне төзәтү; 2. рәтләү, иpләү; *поправить галстук* — галстукны ипләү; 3. яхшырту; *поправить здоровье* — сәламәтлекне яхшырту.

**ПОПРА'ВИТЬ** II *сов.*— тотып бару, бераз тотып бару (дилбегәсен яки рулен); *поправить лошадьми* — бераз ат тотып бару.

**ПОПРА'ВИТЬСЯ** *сов.*— 1. хатаны төзәтү; *умел ошибиться — умей и поправиться* — ялгыша белгәч, хатаны да төзәтә бел; 2. терелү, сәламәтләнү; *он совсем поправился после болезни* — ул авырудан соң бөтенләй сәламәтләнде; 3. тулылану, тазару, симереп китү; *вы очень поправились* — сез бик тазаргансыз; 4. яхшыру, яхшылану, төзәлү; *дела его поправились* — аның эшләре яхшырды. 5. *простореч. фам. (опохмелиться)* баш төзәтү.

**ПОПРА'ВКА** *ж.*— 1. *только ед.*; к. поправление; 2. *(восстановление здоровья)* сәламәтләнү, төзәлү; 3. төзәтмә; *внести поправку в резолюцию* — резолюциягә төзәтмә кертү.

**ПОПРАВЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. төзәтү; *поправление ошибок* — хаталарны төзәтү; 2. сәламәтләнү; *больной пошёл на поправление* — авыру сәламәтләнә башлады.

**ПОПРАВЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. поправить.

**ПОПРАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. төзәлеп килү, яхшыра бару; 2. *страд.* төзәтелү, яхшыртылу.

**ПОПРА'НИЕ** *ср. книж. ритор. устар.*— аяк астына салып таптау (хокукларны, законнарны һ. б.).

**ПОПРА'ТЬ** *сов. книж. ритор.*— к. попирать.

**ПОПРЕ'ЖНЕМУ** *нареч.* — элеккечә, әүвәлгечә.

**ПОПРЁК** *м.*— шелтә, әрләү; *его попрёкам нет конца* — аның әрләвенең чиге юк.

**ПОПРЕКА'ТЬ** *несов.*— шелтәләү, әрләү, битәрләү.

**ПОПРЕКНУ'ТЬ** *сов.*— әрләп кую, әрләп алу, битәрләп кую, шелтәләп кую, шелтәләп алу.

**ПОПРЕ'ТЬ** *сов.*— 1. үз парында пешү, изрәп пешү; 2. *простореч. (попотеть)* тирләү, бераз тирләү.

**ПОПРИВЫ'КНУТЬ** *сов. разг.*— әкренләп күнегү, әкренләп өйрәнү, әкренләп ияләшү.

**ПОПРИДЕРЖА'ТЬ** *сов. разг.*— 1. бераз тота төшү; бераз туктата төшү, бераз акрынайта төшү; *попридержи лошадей* — атларны бераз тота төш; 2. *простореч.* саклап тору, яшереп тору, курсәтми тору; *попридержать товар со спекулятивной целью* — спекуляция максаты белән товарны яшереп тоту.

**ПО'ПРИЩЕ** *ср. книж. ритор.*— мәйдан; *служебное поприще* — хезмәт мәйданы; *научное поприще* — гыйльми эшчәнлек мәйданы.

**ПОПРО'БОВАТЬ** *сов.*— 1. татып карау, тәмен татып карау; *попробовать суп* — ашны татып карау; 2. теләп карау, алынып карау; *попробовать возражать* — каршы эндәшергә теләп карау; 3. сынап карау, чамалап карау; *попробовать, тяжёл ли чемодан* — чемоданның авырлыгын сынап карау. ◇ **Только попробуйте** — тотынып кына карагыз. **Ну-ка тронь, попробуй** — яле, тиеп кара.

**ПОПРОСИ'ТЬ** *сов.*— сорау, сорап алу, сорап карау, үтенү, чакыру, чакырып китерү.

**ПОПРОСИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— рөхсәт сорау, рөхсәт алу.

**ПОПРОСО'ХНУТЬ** *сов. разг.*— бераз кибү, кибә төшү, җилләп алу.

**ПОПРОСТЕ'ТЬ** *сов.*— гадиләшеп китү.

**ПО'ПРОСТУ** *нареч. разг.* — болай гына, тартынмыйча, кыланмыйча, гади генә; *сказать попросту* — гади генә әйтү.

**ПОПРОЧНЕ'ТЬ** *сов.*— ныгып житү, ныгып китү, ныгый төшү.

**ПОПРОША'ЙКА** *м.* и *ж. разг. пренебр.*— 1. *(нищий)* хәерче, теләнче; 2. *фам. (надоедающий просьбами)* соранып йөдәтүче, соранып тенкәгә тиюче.

**ПОПРОША'ЙНИЧАТЬ** *несов. разг. пренебр.*— соранып тенкәгә тию, соранып йөдәтү, теләнү, сорану.

**ПОПРОША'ЙНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *разг. пренебр.*— 1. хәерчелек, теләнчелек; 2. соранып тенкәгә тию, соранып йөдәтү.

**ПОПРОЩА'ТЬСЯ** *сов.*— саубуллашу; *попрощался с хозяином и ушёл* — хужа белән саубуллашты да китте.

**ПОПРЫ'ГАТЬ** *сов.*— сикергәләү, бераз сикергәләү, сикергәләнеп тору; *мальчик попрыгал возле меня и убежал* — малай минем янда бераз сикергәләнеп торды да йөгерде.

**ПОПРЫ'ГИВАТЬ** *несов. разг.*— сикергәләү.

**ПОПРЫГУ'Н** *м.*, **ПОПРЫГУ'НЬЯ** *ж. разг. шутл.* — тиктормас, кыбырсык.

**ПОПРЫ'СКАТЬ** *сов. разг.*— 1. *(обдать мелкими брызгами)* бөркү, сибү; 2. *(о дожде)* сибәләү, сибәләп яву.

**ПОПРЫ'СКАТЬСЯ** *сов. разг.*— сөртенү, бөркү; *попрыскаться одеколоном* — одеколон сөртенү.

**ПОПРЫ'СКИВАТЬ** *несов. разг.*— сирәкмирәк сибү; сирәк-мирәк бөркү.

**ПОПРЯ'ТАТЬ** *сов. разг.*— яшереп бетерү; *попрятали все вещи в подвал* — барлык әйберләрне подвалга яшереп бетергәннәр.

**ПОПРЯ'ТАТЬСЯ** *сов. разг.*— яшеренү, качу; *дети попрятались от дождя* — балалар яңгырдан яшеренделәр.

**ПОПУГА'Й** *м.*— 1. попугай, тутый кош; 2. *перен. разг. пренебр.* попугай, кеше фикерләрен кабатлаучы.

**ПОПУГА'ЙНИЧАТЬ** *несов. разг. фам.*— попугайлану, кемнән ни ишетсә, шуны кабатлау (аңламыйча).

**ПОПУГА'ТЬ** *сов. разг.*— бераз куркыту, бераз куркытып алу.

**ПОПУ'ГИВАТЬ** *несов. разг.*— куркыткалаштыру, сирәк-мирәк куркыткалау.

**ПОПУ'ДНО** *нареч. спец.*— пот исәбеннән; *платить за перевозку товара попудно* — товарны ташыган өчен пот исәбеннән түләү.

**ПОПУ'ДРИТЬ** *сов.*— бераз пудра сөртү, бераз пудра ягу.

**ПОПУ'ДРИТЬСЯ** *сов.*— бераз пудра сөртенү.

**ПОПУЛЯРИЗА'ТОР** *м.*— популярлашты-

ручы; *популяризатор идей Дарвина* — Дарвин идеяләрен популярлаштыручы.

**ПОПУЛЯРИЗА'ЦИЯ** *ж.* — 1. популярлаштыру; 2. *(популярная книга)* популяр китап.

**ПОПУЛЯРИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — популярлаштыру, аңлатып бирү (берәр фикерне халыкка тарату, халыкка аңлаешлы җиңел телдә язып яки сөйләп бирү).

**ПОПУЛЯРИЗИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.* — популярлаштырылу.

**ПОПУЛЯРИЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.* — к. популяризировать.

**ПОПУЛЯРИЗОВА'ТЬСЯ** *несов.* — популярлашу.

**ПОПУЛЯ'РНИЧАТЬ** *несов. разг. пренебр.* — үзен танытырга тырышу, үзен күрсәтергә тырышу, шөһрәт казанырга тырышу.

**ПОПУЛЯ'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. популярлык, аңлаешлылык, барлык кешеләргә аңлаешлы булу, төшенерлек булу; *популярность изложения* — сөйләүнең яки язуның аңлаешлылыгы; 2. *(слава, известность)* шөһрәт, дан, танылганлык, популярлык.

**ПОПУЛЯ'РНЫЙ** — популяр (1. һәркемгә дә аңлаешлы; 2. һәркемгә дә билгеле, киң таралган; *популярный журнал* — һәркемгә билгеле журнал).

**ПОПУР(Р)И'** *ср. нескл.* — попури (1. төрле көй өзекләрен бер-бер артлы тезеп язылган музыка әсәре; 2. *разг. шутл. пренебр.* корама, төрле кисәкләрдән ясалган нәрсә).

**ПОПУСКА'ТЬ** I. *несов. разг.* — к. попустить.

**ПОПУСКА'ТЬ** II *сов. разг.* — җибәрү, җибәреп алу; *попускать мыльные пузыри* — сабын куыклары җибәреп алу.

**ПОПУСТИ'ТЕЛЬ** *м. книж. устар.* — ирек куючы, юл куючы, узындыручы.

**ПОПУСТИ'ТЕЛЬСКИЙ** — ирек кую ...-ы; юл кую ...-ы; *попустительские действия* — ирек кую (эшләре).

**ПОПУСТИ'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.* — ирек куючылык, юл куючылык, узындыру (ярамаган эшләр эшләүгә).

**ПОПУСТИ'ТЕЛЬСТВОВАТЬ** *несов. книж.* — юл кую, ирек кую (ярамаган эшләргә), узындыру.

**ПОПУСТИ'ТЬ** *сов. книж. устар.* — ирек кую, юл кую, узындыру, йомшаклык күрсәтү, тыймау; *как же вы попустили такому беззаконию* — ничек сез мондый законсызлыкка ирек куйдыгыз.

**ПОПУСТО'МУ** *нареч. разг.* — бушка, юкка, корыга, әрәмгә; *нечего время попусту тратить* — юкка вакыт әрәм итәргә ярамый.

**ПО'ПУСТУ** *нареч.* — юкка, бушка.

**ПОПУ'ТАТЬ** *сов. разг.* — 1. *(спутать, замотать)* чуалту, чорнау, бәйләп кую; 2. *перен. (замешать в неприятном деле)* бутау, катнаштыру, юлдан яздыру; 3. котырту, аздыру, вәсвәсәләү; *враг попутал, видно* — дошман котырткан булса кирәк.

**ПОПУ'ТАТЬСЯ** *сов. простореч.* — 1. чуалу, чорналу, чияләнү; *нитки попутались* — җепләр чуалган; 2. буталып йөрү, буталу.

**ПОПУТНИЧЕСКИЙ** — юлаучылык ...; *попутническая литература* — юлаучылык әдәбияты.

**ПОПУ'ТНО** *нареч.* — бер уңайдан, шул ук вакытта; *попутно решили ещё один вопрос* — бер уңайдан тагы бер мәсьәләне хәл иттек.

**ПОПУ'ТНЫЙ** — 1. *(о ветре)* юл уңаена исә торган, арттан исә торган; *попутный ветер* — арттан исә торган җил; 2. бер уңай белән ...-ган; *попутное замечание* — бер уңай белән ясалган замечание. ◇ Попутный вопрос — ияртеп бирелгән сорау.

**ПОПУ'ТЧИК** *м.*, **ПОПУ'ТЧИЦА** *ж.* — 1. юлдаш, бер уңайга баручы; *искать попутчика* — юлдаш эзләү; 2. *перен. презрит.* юлаучы (берәр политик хәрәкәткә вакытлы кушылучы кеше).

**ПОПУЩЕ'НИЕ** *ср. устар.* — 1. к. попустительство; 2. *рел.* каһәр, алланың каһәре.

**ПОПЫТА'ТЬ** *сов.* — 1. *простореч.* сорашып белү, төпченеп белү; *надо дорогу попытать у кого-н.* — берәр кешедән сорашып юлны белергә кирәк; 2. сынап карау; *попытать счастья* — бәхетне сынап карау; 3. газаплап алу, җәзалап карау, җәзалап алу; *попытать преступника* — җинаятьчене җәзалап карау.

**ПОПЫТА'ТЬСЯ** *сов.* — тырышу, тырышып карау, омтылып карау, маташып карау; *попытаться уехать* — китәргә тырышып карау.

**ПОПЫ'ТКА** *ж.* — 1. тырышу, омтылу; *сделать попытку* — тырышып карау; *тщетные попытки* — нәтиҗәсез омтылулар; 2. *(опыт, проба)* тәҗрибә, сынау.

**ПОПЫ'ХИВАТЬ** *несов. разг.* — 1. сирәкмирәк төтен чыгару, төтен чыгаргалау, тәтәтү; *попыхивать из трубки* — трубкадан төтен чыгаргалау; 2. сүнәр-сүнмәс яну; *огонёк попыхивает* — ут сүнәр-сүнмәс яна.

**ПОПЫХТЕ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. *(провести некоторое время, пыхтя)* бераз мышнау; 2. *перен. фам. (потрудиться, стараясь сделать)* маташып карау, тырышып карау, көчәнеп карау.

**ПОПЯ'ТИТЬ** *сов.* — чигендерә төшү, чигендерү.

**ПОПЯ'ТИТЬСЯ** *сов.* — чигенә төшү.

**ПОПЯ'ТНЫЙ** *устар.* — кирегә чигенү...-ы, артка чигенү ...-ы; *попятное движение* — кирегә чигенү хәрәкәте. ◇ На попятный, на попятную или на попятный двор *неодобр.* — кирегә чигенү, үз сүзеннән, фикереннән кире кайту.

**ПОПЯ'ЧИВАТЬ** *несов. разг.* — аз-мазлап чигендерү, акрынлап чигендерү.

**ПО'РА** *ж.* — 1. *анат.* күзәнәк (тир бизләренең тире өстендәге бик вак тишекләре); 2. *физ.* (үсемлекнең, металлның, ташның өстендә яки эчендә) бик вак тишекләр, аралыклар.

**ПОРА'** I *ж.* — вакыт, чак, заман, дәвер; *весенняя пора* — яз вакыты; ночная пора — төнлә. ◇ *В раннюю пору истории* — тарихның борыңгы дәверендә. В поре — чәчәк аткан вакыты; *она т перь девушка в самой поре* — ул кызның хәзер чәчәк

аткан вакыты. **На первых порах** — башта. **В ту пору** — ул вакытта, шул чакта. **В те поры** *обл.* — ул чакта, ул вакытта. **В эту пору** — хәзер. **В самую пору** — нәкъ үз вакытында, нәкъ тиешле вакытында; *вы пришли в самую пору* — сез нәкъ үз вакытында килдегез; **До сих пор** — 1. әлегә кадәр; 2. шушы урынга кадәр. **До тех пор** — шул вакытка кадәр. **До каких пор?** — кайвакытка кадәр? **До поры, до времени** — вакыты җиткәнче. **С тех пор** — шуннан соң. **С той поры** — шул вакыттан бирле, шул заманнан бирле. **С каких пор** — кайчаннан бирле. **С этих пор** — шушы вакыттан бирле. **С давних пор** — бик күптәннән, борынгыдан. **О сю пору** — хәзергә кәнгә кадәр. **С давних пор** — күптәннән, әллә кайчаннан.

**ПОРА' II** *в знач. сказуемого* — вакыт; *пора обедать* — төшке аш ашарга вакыт; *пора ехать* — китәргә вакыт. ◇ **Пора и честь знать** *разг. фам.* — туктарга вакыт, җитәр инде.

**ПОРАБА'ТЫВАТЬ** *несов. разг. фам.* — аз-маз эшләү, эшләштергәләү.

**ПОРАБО'ТАТЬ** *сов.* — бераз эшләү, эшләп алу; *поработать три часа* — өч сәгать эшләп алу; *поработайте ещё немного* — тагын бераз эшләп алыгыз.

**ПОРАБОТИ'ТЕЛЬ** *м. книж. ритор.* — кол итүче, коллыкка төшерүче.

**ПОРАБОТИ'ТЬ** *сов. книж.* — кол итү, коллыкка төшерү.

**ПОРАБОТИ'ТЬСЯ** *сов. книж. устар.* — буйсыну, коллыкка бирелү.

**ПОРАБОЩА'ТЬ** *несов. книж.* — к. поработить.

**ПОРАБОЩА'ТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. *устар.* к. поработиться; 2. *страд.* кол ителү, коллыкка төшерелү.

**ПОРАБОЩЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — к. поработить, порабощать.

**ПОРАВНЯ'ТЬ** *сов.* — тигезләү; *поравнять концы верёвок* — бауларның очларын тигезләү.

**ПОРАВНЯ'ТЬСЯ** *сов.* — тигезләнү; арттан килеп җитү, турысына барып җитү; *когда поравнялся со мною, он поздоровался* — турыма килеп җиткәч, ул минем белән исәнләште.

**ПОРАДЕ'ТЬ** *сов. разг.* — ярдәм итү, булышу.

**ПОРА'ДОВАТЬ** *сов.* — шатландыру, куандыру, сөендерү.

**ПОРА'ДОВАТЬСЯ** *сов. разг.* — куану, шатлану, сөенү.

**ПОРАЖА'ТЬ** *несов.* — к. поразить.

**ПОРАЖА'ТЬСЯ** *несов.* — к. поразиться.

**ПОРАЖЕ'НЕЦ** *м. полит.* — пораженчество тарафдары.

**ПОРАЖЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед.* тидерү; *поражение цели* — төзәгән урынга тидерү; 2. тар-мар ителү, җиңелү, уңышсызлыкка очрау; *поражение в борьбе* — көрәштә җиңелү; 2. *мед.* зарарлану; *поражение зрительного нерва* — күрү нервларының зарарлануы. ◇ **Поражение прав или в правах** — хокуктан мәхрүм итү.

**ПОРАЖЕ'НЧЕСКИЙ** *полит.* — пораженчество...-ы; *пораженческие идеи* — пораженчество идеяләре.

**ПОРАЖЕ'НЧЕСТВО** *ср. полит.* — пораженчество (империалистик сугышта үз хөкүмәтеңнең җиңелүен һәм империалистик сугышны гражданнар сугышына әверелдерүне яклау политикасы; бу политика, рус — япон сугышы һәм I империалистик сугыш елларында II Интернационал партияләренең, рус меньшевикларының һәм эсерларының үз илләрендәге буржуазиянең империалистик интересларын яклап чыккан хыянәтчел политикасына каршы буларак, большевиклар тарафыннан алга сөрелде).

**ПОРАЗВЕ'ДАТЬ** *сов. разг. фам.* — сораштырып белү, разведка ясау, күзәтеп белү.

**ПОРАЗВЛЕ'ЧЬ** *сов. разг. фам.* — бераз күңелен ачып җибәрү, бераз күңелен күтәреп алу.

**ПОРАЗВЛЕ'ЧЬСЯ** *сов. разг. фам.* — бераз күңел ачу, бераз күңел күтәрү.

**ПОРАЗДУ'МАТЬ** *сов. разг. фам.* — уйлаштыру, баш йөртеп карау.

**ПОРАЗДУ'МАТЬСЯ** *сов. разг. фам.* — уйлау, уйлап карау.

**ПОРАЗИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. искиткеч, шаккатыргыч, таң калдыргыч, сокландыргыч, гаҗәп, чиктән ашкан; *поразительная красота* — искиткеч матурлык; *поразительный лентяй* — чиктән ашкан ялкау.

**ПОРАЗИ'ТЬ** *сов.* — 1. *книж. воен.* атып тидерү; сугу, бәрү, чәнчү; *поразить в грудь кинжалом* — хәнҗәр белән күкрәккә чәнчү; 2. *книж.* җиңү; *поразить врага* — дошманны җиңү; 3. *книж.* зарар китерү; *болезнь поразила его слух* — авыру аның колагына зарар китергән; 4. *перен.* гаҗәпкә калдыру, таңга калдыру; *игра артиста поразила всех* — артистның уйнавы бар кешене дә таңга калдырды.

**ПОРАЗИ'ТЬСЯ** *сов.* — ис китү, таңга калу, гаҗәпләнү.

**ПОРАЗМЫ'СЛИТЬ** *сов. разг.* — яхшылап уйлау, выклап уйлау, төпле итеп уйлау, яхшылап фикер йөртеп карау.

**ПОРАЗМЯ'ТЬ** *сов. разг. фам.* — язылдыру, йомшарту; *поразмять ноги* — аякларны язылдыру.

**ПОРАЗМЯ'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.* — сөякләрне бераз язылдыру, бераз язылу.

**ПОРАЗНЮ'ХАТЬ** *сов. простореч. фам.* — тикшеренеп белү, искәнеп белү, сиздермичә төпченеп белү.

**ПОРА'НИТЬ** *сов.* — яралау, җәрәхәтләү.

**ПОРА'НИТЬСЯ** *сов. разг.* — яралану, җәрәхәтләнү.

**ПОРАСКИДА'ТЬ** *сов. разг. фам.* — таратып ташлау, туздырып ташлау, төрле якка ыргытып ташлау.

**ПОРАСКИ'НУТЬ** *сов. разг. фам.* — җәеп ташлау, җәеп кую. ◇ **Пораскинуть умом** — уйлап карау, баш йөртеп карау.

**ПОРАСКИ'НУТЬСЯ** *сов. разг.* — җәелү, җәелеп китү, җәелеп яту; *перед нами пораскинулось море* — безнең алда диңгез җәелеп ята иде.

**ПОРАССКАЗА'ТЬ** *сов. разг.* — сөйләп бирү; *есть о чём порассказать* — сөйләп бирер нәрсә күп.

**ПОРАССПРОСИ'ТЬ** *сов. разг.* — җентекләп сорашу, бөтенесеннән сорашып чыгу, яхшылап сорашып белү.

**ПОРАСТА'ТЬ** *несов.* — к. порасти 2.

**ПОРАСТИ'** *сов.* — **1.** үсә төшү, үсә бару; *ты ещё подрастешь год-другой* — син тагы бер-ике ел үсә төшәрсең әле; **2.** үсү, басу, каплау; *тропинки поросли травой* — сукмакларны үлән баскан.

**ПОРАСТИ'ТЬ** *сов.* — бераз үстерү; *рано в школу, надо ещё дома его порастить* — мәктәпкә бирергә иртә әле, аны өйдә бераз үстерергә кирәк.

**ПОРАСТРЕ'СКАТЬСЯ** *сов. разг.* — ярылып бетү, ярдаланып бетү, чатнап бетү, төрле җирләре чатнап бетү, төрле җире ярдалану.

**ПОРА'ТЫЙ** *охот. спец.* — йөгерек, җитез; *поратый пёс* — йөгерек эт.

**ПОРВА'ТЬ** I *сов.* — **1.** ерту; *порвать письмо* — хатны ерту; **2.** өзү; *порвать нитку* — җепне өзү; **3.** *перен.* өзү; *порвать связи* — бәйләнешне өзү; **4.** өзеп җыю; *порвать цветов* — чәчәкләр өзеп җыю; **5.** *разг.* сызлау (шешеп үлек җыйганда); *под пластырем порвёт немного* — пластырь япкач бераз сызлар.

**ПОРВА'ТЬ** II *сов. безл. разг.* — бераз косу; *порвёт немного и станет легче* — бераз коскач, җиңеләеп китәр.

**ПОРВА'ТЬСЯ** *сов.* — **1.** өзелү; *цеп порвалась* — чылбыр өзелде; **2.** ертылу; *пальто порвалось* — пальто ертылды; **3.** *перен.* өзелү, туктау; *связь порвалась* — ара өзелде, бәйләнеш өзелде.

**ПОРЕВЕ'ТЬ** *сов.* — **1.** *(о животных)* кычкырып тору, бераз акырып тору; кычкыру; **2.** *перен. разг. (плакать)* елап алу.

**ПОРЕВНОВА'ТЬ** *сов.* — **1.** бераз көнләү; **2.** *книж. устар. (проявить заботу)* кайгырту; **3.** *книж. устар. (проявить усердие)* тырышлык күрсәтү.

**ПОРЕДЕ'ТЬ** *сов.* — бераз сирәкләнү, бераз сирәкләнә төшү.

**ПОРЕДИ'ТЬ** *сов. обл.* — бераз сирәгәйтү, бераз сирәкләү, бераз сирәкләндерү.

**ПОРЕ'З** *м.* — **1.** *только ед.* к. *порезать* 3; **2.** киселгән урын; киселгән яра; *болит порез на руке* — кулның киселгән урыны авырта.

**ПОРЕ'ЗАТЬ** *сов.* — **1.** кисү; *порезать хлеба* — икмәк кисү; **2.** (берникадәр вакыт) кискәләү, кискәләп алу; *ты отдохни, а я порежу* — син ял ит, мин кискәләрмен; **3.** яралау, җәрәхәтләү; *порезать руку ножом* — кулны пычак белән яралау; **4.** *разг.* күп итеп сую; *порезать кур* — күп итеп тавык сую.

**ПОРЕ'ЗАТЬСЯ** *сов.* — **1.** киселү, яралану; *порезаться стеклом* — пыялага киселү; **2.** *разг. фам.* дөньясын онытып уйнау, онытылып уйнау (берәр төрле уенны); **3.** *школьн. арго (не выдержать экзамена)* имтихан бирә алмау.

**ПОРЕЗВИ'ТЬСЯ** *сов.* — бераз шаярып алу, бераз уйнап алу.

**ПОРЕ'Й** *м. бот.* — ялпак суган, тасма кыяклы суган.

**ПОРЕКОМЕНДОВА'ТЬ** *сов.* — **1.** рекомендовать итү, тәкъдим итү; *порекомендовать опытного работника* — тәҗрибәле работникны тәкъдим итү; **2.** *книж.* киңәш бирү; *порекомендовать прочесть новую книгу* — яңа китапны укып чыгарга киңәш бирү.

**ПОРЕ'ЧНИК** *м. спец. устар.* — елга буе сукмагы (бурлаклар йөри торган сукмак).

**ПОРЕ'ЧЬЕ** *ср. обл.* — елга буе.

**ПОРЕШИ'ТЬ** *сов.* — **1.** *разг.* сүз куешу, карар итү, ...- га булу; *порешили с утра начать сев* — иртәдән чәчүгә тотынырга булдык; **2.** *устар.* тәмамлау; *порешить дело* — эшне тәмамлау; **3.** *перен. просторeч.* үтерү.

**ПОРЖА'ВЕТЬ** *сов. разг.* — к. заржаветь.

**ПОРЖА'ТЬ** *сов.* — бераз кешнәү, бераз кешнәп алу.

**ПОРИСОВА'ТЬ** *сов.* — бераз рәсем төшереп алу, бераз рәсем ясап алу.

**ПОРИСОВА'ТЬСЯ** *сов.* — бераз кыланып алу.

**ПОРИСО'ВЫВАТЬ** *несов. разг.* — сирәк-мирәк рәсем төшергәләү, сирәк-мирәк рәсем ясаштыргалау.

**ПО'РИСТОСТЬ** *ж. мн.* нет — күзәнәкле булу.

**ПО'РИСТЫЙ** — күзәнәкле; *пористая сталь* — күзәнәкле корыч.

**ПОРИЦА'НИЕ** *ср. книж.* — шелтә; *выразить порицание* — шелтә белдерү.

**ПОРИЦА'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — шелтәле; *порицательный тон* — шелтәле тон.

**ПОРИЦА'ТЬ** *несов. книж.* — шелтәләү, орышу, әрләү.

**ПОРИЦА'ТЬСЯ** *несов. книж. страд.* — шелтәләнү.

**ПО'РКА** I *ж. мн.* нет — сүтү (җөйне).

**ПО'РКА** II *ж. разг. вульг.* — кыйнау, суктыру.

**ПОРНО'ГРАФ** *м. книж. презрит.* — порнограф (порнографик әдәбиятны яратучы, порнографик әсәрләр язучы).

**ПОРНОГРАФИ'ЧЕСКИЙ** — порнографик, әдәпсез, оятсыз; *порнографическая литература* — порнографик әдәбият.

**ПОРНОГРА'ФИЯ** *ж. мн.* нет — порнография (әдәпсезлек, оятсызлык; әдәпсез, оятсыз әдәбият).

**ПО'РОВНУ** *нареч.* — бертигез, тигез итеп; *все получили поровну* — барысы да бертигез алдылар.

**ПОРОВНЯ'ТЬ** *сов. просторeч.* — тигезләү, тигез итү.

**ПОРО'Г** *м.* — **1.** *(у двери)* бусага; *запнуться о порог* — бусагага абыну; **2.** бусага (елганың ташлы сай урыны); *днепровские пороги* — Днепр бусагалары; ◇ **Обивать пороги** — к. обивать. **За порог** — куып чыгару. **На порог не пускать** *разг.* — ишектән дә кертмәү, аяк бастырмау. **На пороге смерти** — кабер якасында.

**ПОРО'ДА** *ж.* — **1.** *(у животных, растений)* токым, нәсел; *порода хвойных деревьев* — ылыслы агачлар токымы; **2.** *разг.* гәүдә, буй; *крупная порода людей* — зур гәү-

дәле кешеләр; 3. *спец.* токым; *горные породы* — тау токымнары; 4. к. породистость.

**ПОРО'ДИСТОСТЬ** *ж.* — саф нәселлелек, саф токымлылык.

**ПОРО'ДИСТЫЙ** — саф токымлы, саф нәселле, саф нәселдән булган; *породистая лошадь* — саф токымлы ат.

**ПОРОДИ'ТЬ** *сов.* — 1. *устар.* к. родить; 2. *перен. книж.* тудыру, китереп чыгару, сәбәп булу; *неудачная формулировка может породить ряд недоразумений* — уңышсыз формулировканың күп кенә аңлашылмаулар китереп чыгаруы мөмкин.

**ПОРОДНИ'ТЬ** *сов.* — туганлаштыру, туганлык мөнәсәбәтләре булдыру.

**ПОРОДНИ'ТЬСЯ** *сов.* — туганлашу, берберенә кардәш булып китү, туганлык мөнәсәбәтләренә керү.

**ПОРО'ДНОСТЬ** *с.-х.* — саф токымлылык, билгеле бер токымнан булу; *учёт породности скота* — токымнарына карап терлекләрнең исәбен алу.

**ПОРО'ДНЫЙ** — токымлы; *породный скот* — токымлы терлек.

**ПОРОЖДА'ТЬ** *несов.* — к. породить.

**ПОРОЖДА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — тудырылу, барлыкка китерелү.

**ПОРОЖДЕ'НИЕ** *ср. книж.* — тудырган нәрсә, ... нигезендә барлыкка килгән нәрсә; *безработица — порождение капитализма* — эшсезлек — капитализм тудырган нәрсә. ◇ **Порождение больной фантазии** — авыру фантазия җимеше.

**ПОРО'ЖИСТОСТЬ** *ж. мн.* нет — ташлы сай урыннар күп булу; бусагалылык; *порожистость рек мешает судоходству* — елгаларда ташлы сай урыннар күп булу пароходлар йөрешенә комачаулый.

**ПОРО'ЖИСТЫЙ** — ташлы сай урыннары күп булган, бусагалы; *порожистая река* — бусагалы елга.

**ПОРОЖНЁМ** *нареч. простореч.* — к. порожняком.

**ПОРО'ЖНИЙ** *разг.* — 1. буш; *порожний ящик* — буш ящик; 2. *обл.* кысыр; йөккә узмаган, корсакка калмаган; *за четыре года она родила двух девочек и уже снова ходила не порожней (М. Горький)* — дүрт ел эчендә ике кыз бала тапты, хәзер тагы йөккә узган инде. ◇ **Переливать из пустого в порожнее** *разг.* — юкны бушка аудару, иләктәген чиләккә бушату.

**ПОРОЖНЯ'К** *м. спец. ж.-д.* — буш состав, буш вагоннар; *на станции нет порожняка* — станциядә буш состав юк.

**ПОРОЖНЯКО'М** *нареч. разг.* — буш (йөксез, йөк төямичә).

**ПО'РОЗ** *м. обл.* — 1. ата дуңгыз, печмәгән ата дуңгыз; 2. үгез.

**ПО'РОЗНУ** *нареч. простореч. устар.* — һәркем үзенчә, үз белдегенчә, төрлечә; *порознy думать — вместе не жить* — һәркем үзенчә уйласа, бергә яшәп булмый.

**ПО'РОЗНЬ** *нареч.* — аерым, ялгыз-ялгыз, берәм-берәм, берәмләп; *не входите сразу, а порознь* — берьюлы кермәгез, берәмләп керегез.

**ПОРОЗОВЕ'ТЬ** *сов.* — алсуланып китү.

**ПОРО'Й** *нареч.* — кайчакта, кайвакыт, вакыт-вакыт; *порой сквозь тучи выглянет луна (А. Толстой)* — кайчакта болытлар арасыннан ай күренеп куя.

**ПОРО'К** *м.* — 1. кимчелек, җитешсез як; *у него один порок — болтливость* — аның бер җитешсез ягы бар — телен тыя алмый; 2. бозыклык, әхлаксызлык; *предаться пороку* — бозыклыкка бирелү; 3. гарипләк; *кривизна ног небольшой порок* — кәкре аяклы булу зур гарипләк түгел. ◇ **Порок сердца** — йөрәк авыруы.

**ПОРО'М** — к. паром.

**ПО'РОНЦЫ** *ед.* нет, *разг. фам. шутл.* — суктыру, кыйнау.

**ПОРОНЯ'ТЬ** *сов. разг.* — төшереп бетерү; *поронял все ложки* — барлык кашыкларны төшереп бетергән.

**ПОРОПТА'ТЬ** *сов. разг.* — рәнҗеп алу, бераз рәнҗеп алу, бераз сукранып алу.

**ПО'РОС** *м.* — к. пороз.

**ПОРОСЁНОК** *м.* — 1. дуңгыз баласы; 2. *перен. разг. фам. шутл.* дуңгыз, шакшы бала; *ах ты, поросёнок! где перепачкался?* — ах дуңгыз, кайда болай пычранып беттең син?

**ПОРОСИ'ТЬСЯ** *несов.* — балалау (дуңгыз турында әйтелә).

**ПО'РОСЛЕВЫЙ** *с.-х. бот.* — үсенте...-ы; үсенте бирү...-ы; *порослевая способность деревьев* — агачларның үсенте бирү сәләте.

**ПО'РОСЛЬ** *ж.* — 1. *только ед.* үсенте (киселгән агачның тамырыннан үсеп чыккан вак үсенте); 2. *(молодой лес)* яшь урман; 3. *(кустарник, заросль)* әрәмәлек, куаклык.

**ПОРО'СЫЙ** *обл.* — буаз (дуңгыз турында әйтелә).

**ПОРОСЯ'** *ср. обл.* — к. поросёнок.

**ПОРОСЯ'ТИНА** *ж. разг.* — 1. дуңгыз баласы ите; 2. *фам. шутл.* дуңгыз; *ах, ты поросятина!* — әй син, дуңгыз!

**ПОРОСЯ'ТНИК** *м. с.-х.* — дуңгыз балалары абзары.

**ПОРОСЯ'ЧИЙ** — дуңгыз баласы...-ы; *поросячий визг* — дуңгыз баласы чыелдавы.

**ПОРО'ТЬ** I *несов.* — 1. сүтү; *пороть старое пальто* — иске пальтоны сүтү; 2. *разг.* (элэктереп) ерту, өзү, эләктереп өзү; *только одежду порет, лазя по деревьям* — агачка менеп йөреп киемен ертырга гына белә. ◇ **Пороть чушь (или вздор или дичь)** — юк-барны сөйләү, борчак ату. **Пороть горячку** — к. горячка.

**ПОРО'ТЬ** II *несов. разг. вульг.* — суктыру (чыбык яки камчы белән).

**ПОРО'ТЬСЯ** I *несов.* — сүтелү.

**ПОРО'ТЬСЯ** II *несов. страд. разг. вульг.* — (камчы яки чыбык белән) суктырылу.

**ПО'РОХ** *м. мн.* нет — 1. дары; 2. *перен.* кызу, бик тиз кабынып китүчән (кеше турында); бик коры, дөрләп янып китә торган (утын турында). ◇ **Порох даром тратить** *разг.* — әрәмгә сөйләү, әрәмгә эшләү. **Не хватает пороха** *разг.* — көче җитми, кулыннан килми, куәте җитми. **Ни синь**

**пороха** *разг.* — бернәрсә дә; *ну, помру, и — ни синь пороха после меня не останется* (М. Горький) — я, үләрмен дә, дөньяда миннән бернәрсә дә калмас. **Нюхать порох** — к. нюхать. **Порохом пахнет** — сугыш жиле исә. **Пороха не выдумает** — к. выдумать. **Держать порох сухим** — дарыны коры тоту, сугышка һәрвакыт әзер булу, сугышка һәрвакыт әзер тору.

**ПОРОХОВНИ'ЦА** *ж.* — дары савыты. ◇ **Есть ещё порох в пороховницах** *перен.* — бездә көч бар әле, дары савытында дары бар әле.

**ПОРОХОВО'Й** — дары...-ы; *пороховой дым* — дары төтене.

**ПОРО'ЧИТЬ** *несов.* — 1. яраксыз дип табу, яраксызга чыгару; *порочить хорошую работу* — яхшы эшне яраксыз дип табу; 2. хурлау, яман атын сату, яманлау; *порочить человека* — кешенең яман атын сату.

**ПОРО'ЧИТЬСЯ** *несов. страд.* — яраксыз дип табылу, яраксызга чыгарылу; хур ителү, яман аты сатылу.

**ПОРО'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. бозыклык, әхлаксызлык; *порочность натуры* — табигатенең бозыклыгы; 2. кимчелек, хаталык; *порочность механистического метода* — механистик методның хаталыгы.

**ПОРО'ЧНЫЙ** — 1. әдәпсез, бозык; *порочный человек* — бозык кеше; 2. *(имеющий недостатки)* кимчелекле, җитешсез, ялгыш, хата.

**ПОРО'ША** *ж. мн.* нет — кырпак кар, яңа яуган йомшак кар.

**ПОРОШИ'НА** и **ПОРОШИ'НКА** *ж. разг. обл.* — дары бөртеге; порошок бөртеге; тузан бөртеге; *порошина в глаз попала* — күзгә тузан бөртеге керде.

**ПОРОШИ'ТЬ** *несов.* — (вак-вак, сирәк) яву, төшү; *путь снежком порошит* — юлга вак-вак кар төшә.

**ПОРОШКО'ВЫЙ** *спец.* — порошок...-ы; *порошковое лекарство* — порошок дару.

**ПОРОШКООБРА'ЗНЫЙ** — порошоксыман; *порошкообразное вещество* — порошоксыман матдә.

**ПОРОШО'К** *м.* — порошок (төеп, тузан яки он кебек вакланган нәрсә); *зубной порошок* — теш порошогы. ◇ **Растереть в порошок** — көлен күккә очыру, тар-мар итү.

**ПОРО'Ю** *нареч.* — к. порой.

**ПОРРЕ'Й** — к. порей.

**ПОРСК** *м.*, **ПОРСКА'НЬЕ** *ср. охот.* — к. порскать.

**ПО'РСКАТЬ** *несов.* — к. порскнуть.

**ПОРСКА'ТЬ** *несов. охот.* — өстерү, ауда җәнлеккә эт өстерү.

**ПО'РСКНУТЬ** *сов. обл.* — 1. *(фыркнуть от смеха)* пырхылдап көлеп җибәрү; 2. чәнчү; сугу; *порскнуть ножом в драке* — сугышканда пычак белән чәнчү; 3. сикерү, ташлану; *порскнуть в сторону* — читкә ташлану.

**ПОРСКНУ'ТЬ** *сов. однокр.* — к. порскать.

**ПОРТ** *м.* — 1. порт (пароходлар, корабльләр килеп туктау өчен ясалган махсус урын; 2. *мор.* корабльдә туп көпшәсе чыгып тору өчен ясалган тишек). ◇ **Естественный порт** — табигый порт (пароходлар туктау өчен уңайлы урын). **Воздушный порт** — һава порты.

**ПО'РТА** *ж. истор.* — Порта (солтан Төркиясе хөкүмәтенең рәсми исеме).

**ПОРТА'Л** *м.* — портал (1. *архит.* зур йортларда парадный ишек; 2. *тех.* күтәрү краны урнаштырылган махсус арба).

**ПОРТА'ЛЬНЫЙ** *архит. тех.* — портал...-ы; *портальные колонны* — портал колонналары.

**ПОРТАТИ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет — портативлык, күләме зур булмау, күләме кечкенә булу; *главное достоинство дорожной вещи — ее портативность* — юл әйберенең иң яхшы ягы — күләме зур булмау.

**ПОРТАТИ'ВНЫЙ** — портатив, кечкенә, йөртергә уңайлы, зур булмаган.

**ПОРТА'Ч** *м. просторeч. бран.* — булдыксыз, әйбер бозучы (эшче).

**ПОРТА'ЧИТЬ** *несов. просторeч. бран.* — бозу, начар эшләү, начар ясау.

**ПОРТБУКЕ'Т** *м. устар.* — портбукет (бүләк итеп бирелә торган букетны салу өчен кәгазь ваза).

**ПОРТВЕ'ЙН** *м.* — портвейн (эчемлек).

**ПО'РТЕР** *м. мн.* нет — портер (кара сыра).

**ПО'РТИК** *м. архит.* — портик (бинага тоташтырылып, түбәсе ябылып эшләнгән колонналы галерея).

**ПО'РТИТЬ** *несов.* — 1. бозу, ярамас хәлгә китерү; *портить машину* — машинаны бозу; *портить здоровье* — сәламәтлекне бозу; *портить отношения* — араны бозу; *портить настроение* — кәефне бозу; *портить ребёнка баловством* — баланы иркәләп бозу; 2. *обл.* сихерләп бозу. ◇ **Портить кровь** — к. кровь.

**ПО'РТИТЬСЯ** *несов.* — бозылу; *мясо быстро портится* — ит бик тиз бозыла; *отношения стали портиться* — ара бозыла башлады.

**ПОРТКИ'** *ед.* нет, *просторeч.* — к. порты.

**ПОРТМОНЕ'** *ср.* — портманит (акча салу өчен).

**ПОРТНИ'ХА** *ж.* — тегүче (хатын-кыз).

**ПОРТНИ'ШКА** *ж. просторeч. пренебр.* — тегүче кисәге, начар тегүче (хатын-кыз).

**ПОРТНО'ВСКИЙ** — 1. тегүче...-ы; тегүчеләр...-ы; *портновские ножницы* — тегүчеләр кайчысы; 2. тегү...-ы; *портновская мастерская* — тегү мастерское.

**ПОРТНО'Й** *м.* — тегүче; *дамский портной* — хатын-кызлар киеме тегүче.

**ПОРТНЯ'ГА** *м. просторeч. пренебр.* — начар тегүче.

**ПОРТНЯ'ЖИЙ** *устар.* — к. портняжный.

**ПОРТНЯ'ЖИТЬ** *несов.* — 1. *просторeч.* тегүчелек итү, тегүчелек эше белән көн күрү; 2. *разг. шутл.* *(шить, чинить)* тегү, ямау.

**ПОРТНЯ'ЖКА** *м. просторeч. пренебр.* — тегүче кисәге, начар тегүче.

**ПОРТНЯ'ЖНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет — тегүчелек, тегүчелек эше белән шөгыльләнү.

**ПОРТНЯ'ЖНЫЙ** — тегүчелек...-ы; *портняжное дело* — тегүчелек эше.

**ПО'РТО** *ср. нескл.* — порто (клиент тарафыннан түләнә торган почта һәм телеграф расходлары).

**ПОРТОВИ'К** *м.* — портчы (портта эшләүче, портта хезмәт итүче).

**ПОРТОВО'Й** и (чаще) **ПОРТО'ВЫЙ** — 1. порт...-ы; *портовые рабочие* — порт эшчеләре; 2. портлы; *портовой город* — портлы шәһәр.

**ПОРТОВСКО'Й** *простореч.* — к. портовой 1.

**ПОРТОМО'ЙКА** *ж. устар.* — к. портомоя.

**ПОРТОМО'ЙНЯ** *ж. устар.* — кер юа торган урын, кер чайкый торган урын (елгада).

**ПОРТОМО'Я** *ж. устар.* — кер юучы.

**ПО'РТО-ФРА'НКО** *ср. нескл.* — портофранко (1. портның пошлинасыз товар йөртү хокукы; 2. чит ил товарларын пошлинасыз кертергә хокуклы порт).

**ПОРТО'ЧИНА** *ж. простореч.* — штан балагы.

**ПОРТПАПИРО'С** *м. устар.* — папирос савыты.

**ПОРТПЛЕ'Д** *м.* — юлчылар сумкасы, юл капчыгы.

**ПОРТРЕ'Т** *м.* — портрет (1. кеше рәсеме; 2. *перен.* әдәби портрет, әдәби әсәрдә персонажның тышкы кыяфәтен сурәтләү; *Гоголь был мастером литературного портрета* — Гоголь әдәби портрет мастеры иде). ◇ **Живой портрет** — к. живой.

**ПОРТРЕТИ'РОВАТЬ** *несов. спец.* — (берәр кешенең) рәсемен ясау.

**ПОРТРЕТИ'СТ** *м.*, **ПОРТРЕТИ'СТКА** *ж.* — портретчы, портрет ясаучы (портрет ясаучы художник).

**ПОРТРЕ'ТНАЯ** *в знач. сущ.* — портретлар бүлмәсе (дворяннар йортларында ата-бабаларының портретлары эленгән бүлмә).

**ПОРТРЕ'ТНЫЙ** — портрет...-ы; портретлар...-ы; *портретная галерея* — портретлар галереясе. ◇ **Портретная живопись** — портрет ясау сәнгате.

**ПОРТСИГА'Р** *м.* — портсигар (папирос савыты).

**ПОРТТАБА'К** *м.* — тәмәке савыты.

**ПОРТУГА'ЛКА** *ж.* — португалияле хатын-кыз.

**ПОРТУГА'ЛЬСКИЙ** — Португалия...-ы, португалиялеләр...-ы; *португальский язык* — португалиялеләр теле.

**ПОРТУГА'ЛЬЦЫ** *м.* (*ед.* португалец) — португалиялеләр, Португалия халкы.

**ПОРТУЛА'К** *м. бот.* — портулак (көньякта җиргә ятып үсә торган сусыл яфраклы берьеллык яшелчә).

**ПОРТУПЕ'ЙНЫЙ** *воен.* — портупея...-ы; *портупейный ремень* — портупея каешы.

**ПОРТУПЕ'Й-ПРА'ПОРЩИК** *воен. истор.* — портупей-прапорщик (пехотада подпрапорщик чины).

**ПОРТУПЕ'Й-Ю'НКЕР** *м. дореевол. воен.* — портупей-юнкер (1. революциягә кадәр булган хәрби уку йортларында өлкән юнкер званиесе; 2. *истор.* кавалериядә подпрапорщик чины).

**ПОРТУПЕ'Я** *ж. воен.* — портупея (кылычны яки башка берәр коралны тагып, асып йөри торган каеш яки укалы тасма).

**ПОРТФЕ'ЛЬ** *м.* — 1. портфель; *туго набитый портфель* — дыңгычлап тутырылган портфель; 2. *перен. только ед.* портфель (редакциядә басарга кабул ителгән кулъязмалар); *в портфеле редакции имеется несколько повестей* — редакциянең портфелендә басарга кабул ителгән берничә повесть бар. ◇ **Министр без портфеля** — портфельсез министр (капиталистик илләрдә министр должностеның бер төре).

**ПОРТФЕ'ЛЬНЫЙ** — портфель...-ы; *портфельное производство* — портфель производствосы.

**ПОРТШЕ'З** *м.* — портшез (ярым яткан хәлдә утыру өчен эшләнгән кресло).

**ПОРТЫ'** *ед.* нет, *простореч.* — штан.

**ПОРТЬЕ'** *м. устар.* — швейцар (гостиницада).

**ПОРТЬЕ'РА** *ж.* — портьера (тәрәзә пәрдәсе, ишек чаршавы).

**ПОРТЬЕ'РНЫЙ** — портьера...-ы; *портьерный материал* — портьера материалы.

**ПОРТЯ'НКА** *ж.* — аяк чолгавы, чолгау.

**ПОРТЯ'НОЧНЫЙ** — чолгау...-ы; *портяночный холст* — чолгау киндере.

**ПОРУБА'ТЬ** *сов. обл.* — к. порубить 2.

**ПОРУБЕ'ЖНЫЙ** — чик буендагы; *порубежный город* — чик буендагы шәһәр.

**ПОРУБИ'ТЬ** *сов.* — 1. кисеп бетерү; *порубили молодой лес* — яшь урманны кисеп бетергәннәр; 2. турап бетерү; *кавалеристы в атаке порубили всех солдат противника* — кавалеристлар атакада дошманның барлык солдатларын турап бетергәннәр; 3. бераз кисү; *порубил дров и сел отдыхать* — бераз утын кискәч, ял итәргә утырды.

**ПОРУБИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — кисешү (кылыч белән кисешү).

**ПОРУ'БКА** *ж.* — урлап урман кисү, рөхсәтсез урман кисү.

**ПОРУ'БЛИВАТЬ** *несов. разг.* — кискәләштерү.

**ПОРУ'БЩИК** *м.* — рөхсәтсез урман кисүче.

**ПОРУГА'НИЕ** *ср.* — хурлык, мәсхәрә.

**ПОРУГА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. тиргәү, орышу, сүгү, шелтәләү; 2. *книж. ритор. устар.* (*опозорить*) хур итү, мәсхәрә итү.

**ПОРУГА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. тиргәшү, әрләшү; орышышу; *он любит поругаться* — ул тиргәшергә ярата; 2. *разг. фам.* (*поссориться*) тиргәшеп араны бозу.

**ПОРУ'ГИВАТЬ** *несов. разг.* — тиргәштергәләү, әрләштергәләү.

**ПОРУ'ГИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — тиргәшкәләү, орышышкалау.

**ПОРУ'КА** *ж.* — ышаныч, дәлил; *нет никакой поруки, что сделают в срок* — вакытында эшләүләренә һичбер нинди ышаныч юк. ◇ **Взять на поруки** — порукага алу, үз җаваплылыгына алу.

**ПОРУКОВОДИ'ТЬ** *сов.* — бераз җитәкчелек итү, җитәкчелек итеп алу.

**ПОРУКОВО'ДСТВОВАТЬ** *сов. устар.* — к. поруководить.

**ПОРУМЯ'НИТЬ** *сов.* — бераз кызарту, бераз кызыллandыру, бераз иннек сөртү.

**ПОРУМЯ'НИТЬСЯ** *сов.* — бераз иннек ягыну, кызарыну.

**ПОРУСЕ'ТЬ** *сов.* — конгыртлана төшү, бераз конгыртлану.

**ПОРУ'ХА** *ж. обл. устар.* — жимереклек, бөлгенлек, каза, бәла, зыян, зарар.

**ПОРУЧА'ТЬ** *несов.* — к. поручить.

**ПОРУЧА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — йөкләтелү, тапшырылу.

**ПОРУЧЕ'НИЕ** *ср.* — йөкләмә, йомыш; *дать поручение* — йөкләмә бирү, эш йөкләү, йомыш кушу; *партийное поручение* — партия йөкләмәсе.

**ПО'РУЧЕНЬ** *м.* — тотка, тоткыч, култыкса (баскыч, күпер, пароход һ. б. читләренә тотынып, таянып өчен, егылып төшүдән саклар өчен куелган киртә, буй агач, бау, каеш һ. б.).

**ПО'РУЧИ** *только мн.* — 1. *истор.* металл җиңсәләр (хәрби киемдә); 2. *церк.* укалы җиңсә (архиерей киемендә).

**ПОРУ'ЧИК** *м. дореол.* — поручик (урта дәрәҗәдәге гаскәри чин).

**ПОРУЧИ'ТЕЛЬ** *м. право, офиц.* — җаваплылыкны өстенә алучы, җаваплылыкны үз өстенә йөкләүче, (берәр кеше өчен җаваплылыкны үз өстенә алучы).

**ПОРУЧИ'ТЕЛЬНЫЙ** *право. офиц.* — җаваплылыкны өскә алу...-ы; *поручительное письмо* — җаваплылыкны өскә алу хаты.

**ПОРУЧИ'ТЕЛЬСКИЙ** *право, офиц.* — поручитель...-ы; *поручительская подпись* — поручитель имзасы.

**ПОРУЧИ'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет — 1. *юр.* җаваплылыкны өскә алу (берәр кеше өчен); 2. тәкъдим итү, яхшы рекомендация бирү.

**ПОРУЧИ'ТЬ** *сов.* — 1. йөкләү, тапшыру, кушу; *поручить составление отчёта* — отчёт төзүне тапшыру; 2. карарга бирү; тәрбиягә бирү; *поручил сына воспитателю* — улын тәрбиячегә карарга бирде.

**ПОРУЧИ'ТЬСЯ** *сов.* — к. поручаться.

**ПОРУ'ЧИЦА** *ж. дореол. разг.* — поручик хатыны.

**ПОРУ'ШИТЬ** *сов.* — 1. *обл.* җимерү, вату; *порушить стену* — стенаны җимерү; 2. *книж. устар.* (*нарушить, уничтожить*) бозу, бетерү, юкка чыгару; 3. *спец.* ярдыру; *порушить гречу* — карабодай ярдыру (яргычта).

**ПОРУ'ШИТЬСЯ** *сов.* — 1. *обл.* җимерелү, ватылу; *забор порушился* — койма җимерелде; 2. *книж. устар.* (*нарушиться, уничтожиться*) бетерелү, юкка чыгарылу.

**ПОРФИ'Р** *м.* — порфир (тау токымының бер төре).

**ПОРФИ'РА** *ж.* — порфира (1. *книж.* патшалар киеме; 2. *бот.* диңгездә үсә торган кызыл төстәге суүсем).

**ПОРФИ'РНЫЙ** — 1. порфирдан эшләнгән; 2. порфир төсле, куе кызыл.

**ПОРФИРОНО'СЕЦ** *м. поэт. ритор.* — патша, монарх.

**ПОРФИРОНО'СНЫЙ** *поэт. ритор. устар.* — порфира кигән, патша киеме кигән.

**ПОРФИРОРО'ДНЫЙ** *поэт. устар. ритор.* — патша нәселеннән чыккан; *порфирородный господин* — патша нәселеннән чыккан әфәнде.

**ПОРХА'ТЬ** *несов.* — 1. пыр-пыр очып йөрү, пырылдап очып йөрү, бер урыннан икенче урынга куныл очып йөрү; *порхают воробьи* — чыпчыклар пырылдап очып йөриләр; 2. *перен. разг. шутл. неодобр.* (*вести рассеянный образ жизни*) кәеф-сафада яшәү, ваемсыз яшәү.

**ПОРХУ'НЬЯ** *ж.* — пырылдап очып йөрүче кош.

**ПОРЦИО'Н** *м.* — порцион (1. көнлек азык; 2. к. порция). ◇ **Полевой порцион** *дореол.* — сугышта офицерларга бирелә торган азыклык өстәмә акча.

**ПОРЦИОНИ'СТ** *м. спец.* — порционист (консерваны банкаларга тутыручы эшче).

**ПОРЦИ'ОННЫЙ** — 1. *дореол.* порцион...; өстәмә азыклык...; *порционные деньги* — өстәмә азыклык акча; 2. порцион...; аерым заказ буенча хәзерләнгән; *порционные блюда в ресторане* — ресторанда аерым заказ буенча хәзерләнгән блюдолар, порцион блюдолар.

**ПО'РЦИЯ** *ж.* — порция, өлеш, норма.

**ПО'РЧА** *ж. мн.* нет — 1. (*действие*) к. портить, портиться; 2. *обл.* сихерләп бозу.

**ПО'РЧЕНЫЙ** — 1. бозык, бозылган; *порченое яблоко* — бозылган алма; 2. *обл.* (*больной от колдовства*) сихердән авыруга сабышкан, сихердән бозылган.

**ПО'РШЕНЬ** *м. тех.* — поршень, пешкәк (насоста, пар машинасында һ. б.).

**ПО'РШНИ** *обл.* — каеш чабата (каештан үрелгән чабатасыман аяк киеме).

**ПОРШНЕВО'Й, ПО'РШНЕВЫЙ** *тех.* — поршень...-ы, пешкәк...-ы; поршеньлы, пешкәкле; *поршневая крышка* — пешкәк капкачы.

**ПОРЫБА'ЧИТЬ** *сов. разг.* — бераз балык тоту, бераз балык тотып алу.

**ПОРЫ'В** *м.* — 1. (*действие*) к. порваться 1; 2. кинәт рухланып китү, дәрт, омтылыш; *жить без порывов* — омтылышсыз яшәү. ◇ **Порыв негодования** — ачу кабыну. **Порыв ветра** — кинәт җил исеп кую. **Благие порывы** — яхшы ниятләр. **В порыве гнева** — ачу кабынып киткәндә, ачу катыш.

**ПОРЫВА'ТЬ** *несов.* — өзү; *порывать сношения* — араны өзү, элемтәне өзү.

**ПОРЫВА'ТЬСЯ** I *несов.* — 1. омтылу; *порываться вперёд* — алга омтылу; 2. тырышу, ашкыну, ашкынып тору; *он порывался что-то сказать* — ул нәрсәдер әйтергә ашкынып тора иде.

**ПОРЫВА'ТЬСЯ** II *несов.* — к. порваться.

**ПОРЫ'ВИСТОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. бер көчәя, бер басыла торган булу; *порывистость ветра* — җилнең бер көчәя, бер басыла торган булуы; 2. ашкынучанлык, кискенлек; *порывистость характера* — характерның ашкынучанлыгы; 3. тиз мавы-

гучанлык; *порывистость ребёнка* — баланың тиз мавыгучанлыгы.

**ПОРЫ'ВИСТЫЙ** — 1. бер көчәя, бер басыла торган; *порывистый ветер* — бер көчәя, бер басыла торган җил; 2. ашкынулы, кискен; *порывистые движения* — ашкынулы хәрәкәтләр; 3. ашкынучан, тиз мавыгып китүчән; *порывистый ребёнок* — тиз мавыгып китүчән бала; *порывистый человек* — ашкынучан кеше.

**ПОРЫЖЕ'ЛЫЙ** *разг.* — җирән төскә кергән, уңып саргаеп беткән; *порыжелое пальто* — уңып саргаеп беткән пальто.

**ПОРЫЖЕ'ТЬ** *сов.* — җирән төскә керү, уңып саргаю; *шляпа порыжела* — эшләпә уңып саргайган.

**ПОРЫ'СКАТЬ** *сов. разг.* — эзләп йөрү; *порыскал два дня в поисках нужной книги* — кирәкле китапны ике көн эзләп йөрдем.

**ПОРЫ'ТЬ** *сов.* — бераз чоку, бераз казу; *порыли канаву и бросили* — канауны бераз казыдылар да туктадылар.

**ПОРЫ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. казыну; *петух порылся в навозной куче* — әтәч тирес өемендә казынды; 2. актару; *порылся в карманах* — кесәләрен актарды. ◇ **Порыться в памяти** *разг.* — искә төшерергә тырышу.

**ПОРЯБЕ'ТЬ** *сов.* — чуарлану, чуарланып китү, шадралану, шадраланып китү.

**ПОРЯДИ'ТЬ** *сов. простореч.* — яллау; *порядить извозчика* — извозчик яллау.

**ПОРЯДИ'ТЬСЯ** *сов.* — к. рядиться II.

**ПОРЯ'ДКОВЫЙ**: **порядковый номер** — тәртип номеры; **порядковое числительное** *грам.* — тәртип саны.

**ПОРЯ'ДКОМ** *нареч. разг. фам.* — 1. бик нык, шактый, җитәрлек; *я порядком устал* — мин шактый арыдым; 2. яхшылап, юньләп, рәтләп; *я ничего порядком не узнал* — бернәрсә дә рәтләп белә алмадым.

**ПОРЯ'ДЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — пөхтәлек, тәртип сөю.

**ПОРЯ'ДЛИВЫЙ** — пөхтә, тәртип сөючән; *порядливый человек* — пөхтә кеше.

**ПОРЯ'ДНЫЙ**: **порядная запись, или порядная грамота** *истор.* — порядная грамота (Москва Русенда крестьян белән феодал арасында крестьянның феодалдан китәргә алганы өчен шинди эшләр эшләргә тиеш икәнлеге турында төзелгән договор).

**ПОРЯ'ДОК** *м.* — 1. тәртип; *поддерживать порядок* — тәртип саклау; 2. *только ед.* рәт, тәртип; *в алфавитном порядке* — алфавит тәртибендә; *изложил всё по порядку* — бөтенесен рәттән сөйләп бирде; 3. *только ед.* ысул, юл, рәвеш; *в административном порядке* — административ юл белән; *в порядке контроля* — контроль рәвешендә; 4. режим, тәртип; *старый порядок* — иске тәртип, иске режим; 5. *воен. (построение, строй)* саф, тәртип; 6. рәт; *сажать деревья в два порядка* — агачларны ике рәт итеп утырту; 7. *(обычай, обыкновение)* тәртип, гадәт, гореф-гадәт; 8. *науч. (группа родственных животных)* нәселдәш хайваннар (яки үсемлекләр). ◇ **Затруднения практического порядка** — практик характерда булган кыенлыклар. **Явления одного порядка** — бер үк характердагы күренешләр. **В порядке вещей** *разг.* — табигый; *всё это в порядке вещей, не надо удивляться* — болар барысы да бик табигый, ис китәр нәрсә юк. **В порядке** — тәзек; *вернул велосипед в порядке* — велосипедны төзек килеш кайтарып бирде. **Порядок дня** — көн тәртибе. **Призвать к порядку** — тәртипкә өндәү, тәртипкә чакыру. **Своим порядком** — тиешенчә, тиешлечә, үз җае (унае, юлы) белән. **Одного порядка** — бертесле, бертөрле, бер үк характердагы. **Приводить в порядок** — рәткә салу, тәртипкә китерү. **По порядку** — рәттән, бер-бер артлы. **В плановом порядке** — планлы рәвештә, план буенча.

**ПОРЯ'ДОЧНО** *нареч.* — 1. *разг.* күп кенә, шактый, байтак; *ждать пришлось порядочно* — байтак көтәргә туры килде; 2. *разг.* ярыйсы гына, яхшы; *он пишет порядочно* — ул яхшы яза.

**ПОРЯ'ДОЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — намуслылык, инсафлылык, әдәплелек, кешелек лелек; *никто не сомневался в его порядочности* — аның намуслы булуында беркемнең дә шиге юк иде.

**ПОРЯ'ДОЧНЫЙ** — 1. шактый зур, шактый күп, ярыйсы гына, зур гына; *порядочный доход* — шактый зур доход; 2. *(недурной, достаточно хороший)* ару гына, ярыйсы гына, яхшы гына; *порядочное место* — яхшы гына урын; 3. намуслы, яхшы, ихтирам итәрлек; *порядочный человек* — намуслы кеше; 4. *разг.* иң, гаять, чиктән ашкан, бик; *порядочный бездельник* — чиктән ашкан ялкау, ялкауның ялкавы.

**ПОСА'Д** *м.* — 1. *дореволюц.* бистә, кечкенә шәһәр; 2. *истор.* посад (борынгы Русьта шәһәрнең сәүдә һәм промышленность районы); 3. *устар. (предместье, окраина города)* бистә.

**ПОСАДИ'ТЬ** *сов.* — 1. утырту; *посадить яблоню* — алмагач утырту; *посадить на стул* — урындыкка утырту; *посадить на хлеб и воду* — икмәк белән суга утырту; 2. *устар.* урнаштыру; *поселенцев посадили на новые земли* — күчеп килүчеләрне яңа җирләргә урнаштырдылар; 3. ябу, утырту; *посадить в тюрьму* — төрмәгә ябу; *посадить птицу в клетку* — кошны читлеккә утырту, кошны читлеккә ябу; 4. бәйләп кую; *посадить собаку на цепь* — этне чылбырга бәйләп кую; 5. *разг.* (... итеп) кую; *посадить председателем* — председатель итеп кую; 6. *разг. фам.* төшерү; *посадить пятно на шляпу* — эшләпәгә тап төшерү; 7. кую; утырту; *посадить хлебы в печь* — икмәкләрне мичкә кую; 8. тоту, әрәм итү, сарыф итү (мәсәлән, акчаны); 9. тагу; *посадить пуговицы на пальто* — пальтога төймәләр тагу; 10. *разг. фам.* уңайсыз хәлдә калдыру; *он меня посадил своим вопросом* — үзенең соравы белән ул мине уңайсыз хәлдә калдырды. ◇ **Посадить верхом на лошадь** — атка атландыру. **Посадить в калошу** — к. калоша.

**ПОСА'ДКА** *ж.*— 1. *только ед.* утырту; 2. *спец.* утыртылган үсемлек, агач; 3. кертү, утырту; *началась посадка в вагоны* — вагоннарга кертә башладылар; 4. утыру, төшү; *самолёт сделал посадку на болоте* — самолёт сазлыкка утырды; 5. утыру; *кавалерийская посадка* — ат өстендә кавалеристларча утыру.

**ПОСА'ДНИК** *м. истор.*— посадник (борынгы Русьта—князьнең шәһәр, өлкә белән идарә итү өчен билгеләнгән наместнигы яки вече тарафыннан сайланган шәһәр башлыгы).

**ПОСА'ДНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *истор.*— посадник вазыйфасы, посадник урыны.

**ПОСА'ДОЧНЫЙ** — 1. утыру...-ы; төшү...-ы; *посадочная площадка* — төшү мәйданы (самолётлар өчен); 2. утыртырга билгеләнгән; *посадочные цветы*— утыртырга билгеләнгән чәчәкләр; 3. *спец.* утырту...-ы; *посадочные машины* — утырту машиналары (мәсәлән, бәрәңге утырту машинасы).

**ПОСА'ДСКИЙ** *устар.* — 1. посад...-ы; *посадские люди* — посад халкы (борынгы Русьта шәһәрдә яшәүче сәүдә, промышленность кешеләре); 2. *в. знач. сущ.* посадта яшәүче; 3. *в знач. сущ. обл. бран.* хулиган, дау куптаручы, тупас, тыйнаксыз кеше.

**ПОСАЖА'ТЬ** *сов. разг.*— күп итеп утырту; *посажать гостей* — күп итеп кунаклар утырту; 2. бераз утырту, бераз утыртып алу; *посажать цветов* — бераз чәчәкләр утыртып алу.

**ПОСАЖЕ'ННЫЙ** — сажинлап, сажин исәбеннән; *посаженная плата* — сажин исәбеннән түләү.

**ПОСАЖЁНЫЙ**: **посажёный отец** — туй йоласында „ата" (вәли-вәкил) булып килгән кеше; **посажёная мать** — туй йоласында „ана" булып килгән хатын.

**ПОСА'ЛИВАТЬ** *несов. разг.*— тозлаштыру, сирәк-мирәк тозлау.

**ПОСА'ЛИТЬ** *сов.*— тун май сөртү.

**ПОСА'ПЫВАТЬ** *несов.*— сирәк-мирәк борын сызгырту, сирәк-мирәк мышнау, вакыт-вакыт мышнау, мышнаштыргалау.

**ПОСА'СЫВАТЬ** *несов. разг.*— аз-маз имү, сирәк-мирәк имү, имгәләштерү, суыру; *посасывать трубку* — трубка суыру.

**ПОСА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— сарку, саркып тору; *вода посачивается из бочки*— мичкәдән су саркып тора.

**ПОСБА'ВИТЬ** *сов. разг.*— киметә төшү; *посбавить цену* — бәясен кимеге төшү.

**ПОСБИВА'ТЬ** *сов. разг.*— к. посбить.

**ПОСБИ'ТЬ** *сов. разг. фам.*— төшерү, бәреп төшерү; *посбить спесь кому-н.*— борынын төшерү, һавалануын киметү.

**ПОСВА'ТАТЬ** *сов.*— кыз димләү, димләү, кодалау.

**ПОСВА'ТАТЬСЯ** *сов.*— кыз сорау, яучылау.

**ПОСВЕЖЕ'ТЬ** *сов.*— 1. салкынаю, салкынаеп китү; *к вечеру посвежело* — кичкә таба (көн) салкынаеп китте; 2. яшәреп китү; *она посвежела* — ул яшәреп киткән.

**ПОСВЕТИ'ТЬ** *сов.*— бераз яктырту, бераз яктылык төшереп алу; *луна посветила и скрылась за тучами* — ай бераз яктыртты да болытлар арасына кереп югалды.

**ПОСВЕТЛЕ'ТЬ** *сов.*— яктырып китү; *небо посветлело* — күк йөзе яктырып китте.

**ПОСВЕТЛИ'ТЬ** *сов.*— ялтырату, бераз ялтыратып алу; *посветлить пуговицы* — төймәләрне бераз ялтыратып алу.

**ПО'СВИСТ** *м. спец. обл.*—.... сызгыруы, сызгыру манеры; *соловьиный посвист* — сандугач сызгыруы.

**ПОСВИСТА'ТЬ** *сов.*— 1. к. посвистеть; 2. сызгырып чакыру; *посвистать собак* — этләрне сызгырып чакыру.

**ПОСВИ'СТЫВАТЬ** *несов.*— сызгырыну, сирәк-мирәк сызгыру; *он задумчиво посвистывал* — ул уйланып сызгырына иде.

**ПО-СВО'ЙСКИ** *нареч. разг.*— 1. үзе теләгәнчә; *проучить по-свойски* — үзе теләгәнчә акылга өйрәтү; 2. *простореч.* үз итеп, иптәшләрчә; *скажу тебе по-свойски*— үз итеп әйтәм сиңа, иптәшләрчә әйтәм сиңа.

**ПОСВЯТИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.*— багышлау....-ы; багышлап язылган; *посвятительная надпись* — багышлап язылган язма.

**ПОСВЯТИ'ТЬ** *сов.*— 1. белдерү, таныштыру, ачып бирү; *посвятить в тайны ремесла* — һөнәрнең серен ачып бирү; 2. багышлау; *он посвятил себя науке* — ул үзен фән өлкәсендә эшләүгә багышлаган; 3. *устар.* исем бирү; *посвятить в рыцари* — рыцарь исеме бирү.

**ПОСВЯТИ'ТЬСЯ** *сов. устар.*— исем алу; *посвятиться в дьяконы* — дьякон исеме алу.

**ПОСВЯЩА'ТЬ** *несов.*— к. посвятить.

**ПОСВЯЩА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. *устар.* к. посвятиться; 2. *страд.* багышлану.

**ПОСВЯЩЕ'НИЕ** *ср.* — 1. (*действие*) к. посвятить, посвящать; 2. багышлама, багышланган әсәр (нинди булса да әсәр башында аның берәр кешегә багышлап язылганын яки бүләк ителгәнен белдерә торган язу); *посвящение в стихах* — шигырь белән язылган багышлама.

**ПОСЕ'В** *м. только ед.* — 1. чәчү; *время посева* — чәчү вакыты, чәчү өсте; 2. чәчүлек, чәчелгән ашлык; *озимые посевы* — көз чәчелгән ашлыклар.

**ПОСЕВНО'Й** — 1 чәчү...-ы; *посевная площадь*—чәчү мәйданы; 2. чәчүлек...; *посевной овёс* — чәчүлек солы.

**ПОСЕ'ВЩИК** *м.* — чәчүче, иген чәчүче.

**ПОСЕДЕ'ЛЫЙ** — 1. чәче-сакалы агарган, чал кергән; *поседелый старик* — чәче-сакалы агарган карт; 2. картайган, чәче агарган (берәр эштә); *поседелый в канцеляриях писарь* — канцеляриядә утырып картайган писарь.

**ПОСЕДЕ'ТЬ** *сов.* — 1. агару, чал керү; *волосы поседели* — чәчләре агарган; 2. картаю, чәче агару (бер эшкә нык күнеккән, тәҗрибә алган кеше турында әйтелә).

**ПОСЕДЛА'ТЬ** *сов. воен.* — к. оседлать 1.

**ПОСЕЙЧА'С** *нареч. разг.* — хәзергә ка-

дәр, әлегә чаклы; *и посейчас на заводе работаю* — әлегә чаклы заводта эшлим.

**ПОСЕКРЕ'ТНИЧАТЬ** *сов. разг.* — бераз серләшү, бераз серләшеп алу; икәүдән-икәү генә сөйләшеп алу, колактан-колакка гына сөйләшеп алу, серләшү; *старушка любила посекретничать* — карчык серләшергә бик ярата иде.

**ПОСЕЛЕ'НЕЦ** *м.* — 1. күчеп килеп утырган кеше; *первые русские поселенцы в Сибири* — Себергә беренче буларак күчеп килеп утырган руслар; 2. (*лицо, подвергнутое ссылке*) сөргенгә җибәрелгән кеше. ◇ **Военный поселенец** — хәрби поселениедә торучы.

**ПОСЕЛЕ'НИЕ** *ср.* — 1. (*действие*) к. поселить 1; 2. (*населённый пункт*) авыл, яшәү урыны; 3. *дореол.* сөрген; *отправить на поселение* — сөргенгә җибәрү. ◇ **Военные поселения** *истор.* — хәрби поселениеләр (Александр I заманында генерал Аракчеев тарафыннан кертелгән гаскәр оештыру системасы; бу система нигезендә күп кенә районнарның крестьяннарын солдат ясап, хәрби хезмәтне үтәү белән беррәттән, аларга авыл хуҗалыгы эшләрен үтәү дә бурыч итеп куелган иде).

**ПОСЕЛЁННЫЙ** — 1. поселение...-ы; *поселённые войска* — поселение гаскәрләре; 2. *офиц. устар.* һәр авылга карата төзелгән; *поселённые списки крестьян* — крестьяннарның һәр авылга карата төзелгән исемлекләре.

**ПОСЕЛИ'ТЬ** *сов.* — 1. урнаштыру, торак бирү; *поселить рабочих в новых домах* — эшчеләрне яңа өйләргә урнаштыру; 2. *перен.* тудыру; *поселить вражду* — дошманлык тудыру.

**ПОСЕЛИ'ТЬСЯ** *сов.* — урнашу; *поселиться в гостинице* — гостиницага урнашу.

**ПОСЁЛКОВЫЙ** и **ПОСЕЛКО'ВЫЙ** — посёлок...-ы; *поселковый совет* — посёлок советы.

**ПОСЁЛОК** *м.* — посёлок, авыл (авылдан яки шәһәрдән аерылып чыккан яңа авыл).

**ПОСЕ'ЛЬЩИК** *м. устар.* — к. поселенец.

**ПОСЕЛЯ'НИН** *м. устар. поэт.* — авыл кешесе, крестьян. ◇ **Военный поселянин** — к. военный поселенец.

**ПОСЕЛЯ'НКА** *ж. устар.* и *поэт.* — к. поселянин.

**ПОСЕЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. поселить.

**ПОСЕЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. поселиться; 2. *страд.* урнаштырылу.

**ПОСЕМЕ'ЙНЫЙ** *офиц.* — 1. семья башыннан алына торган; *посемейное обложение* — семья башыннан алына торган налог; 2. һәр семьяга аерым төзелгән; *посемейные списки* — һәр семьяга карата төзелгән исемлек.

**ПОСЕМУ'** *нареч. канц.* — шуңа күрә, шул сәбәпле, шунлыктан.

**ПОСЕРДИ'ТЬ** *сов.* — бераз ачуландыру, бераз ачуын китерү.

**ПОСЕРДИ'ТЬСЯ** *сов.* — бераз ачулану, бераз ачуланып алу.

**ПОСЕРЕБРИ'ТЬ** *сов.* — көмешләү, көмешкә ману, көмеш йөгертү; *посеребрить чайные ложки* — бал кашыкларына көмеш йөгертү.

**ПОСЕРЕДИ'** *нареч. простореч.* — уртада.

**ПОСЕРЕДИ'НЕ** *нареч. разг.* — 1. уртада; *посередине стоял высокий человек* — уртада озын кеше басып тора иде; 2. *в знач. предлога* уртасында; *посередине комнаты стоит стол* — бүлмә уртасында өстәл тора.

**ПОСЕРЁДКЕ** *нареч. простореч.* — к. посередине.

**ПОСЕРЕ'ДЬ** *нареч. обл.* — уртасында.

**ПОСЕРЕ'ТЬ** *сов.* — сорылану, соры төскә керү; караңгылану; *небо посерело* — күк йөзе караңгыланды.

**ПОСЕРЧА'ТЬ** *сов. простореч.* — к. посердиться.

**ПОСЕССИО'ННЫЙ** *истор.* — посессион; *посессионные заводы* — посессион заводлар (үзләре аерым хуҗалар кулында булып та, дәүләт карамагындагы крепостной крестьяннар көченнән файдаланучы заводлар).

**ПОСЕ'ССИЯ** *ж. истор.* — посессия (арендага алынган җир).

**ПОСЕ'ССОР** *м. истор.* — посессор (1. крепостной крестьяннар хезмәте белән файдалана торган завод хуҗасы; 2. кайбер илләрдә җир арендалаучы).

**ПОСЕ'СТРИТЬСЯ** *сов. обл.* — апалы-сеңелле кебек булып китү, дуслашу.

**ПОСЕ'СТЬ** *сов. разг.* — күпләп утыру, күпләп куну (мәсәлән, кошлар).

**ПОСЕТИ'ТЕЛЬ** *м.*, **ПОСЕТИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж.* — килүче, йомыш белән килүче; *посетитель музея* — музей карарга килүче.

**ПОСЕТИ'ТЕЛЬСКИЙ** *спец.* — килүчеләр өчен булган; *посетительский гардероб в больнице* — больницада килүчеләр өчен булган гардероб.

**ПОСЕТИ'ТЬ** *сов. книж.* — 1. йомыш белән килү, йомыш белән бару, күрергә бару, барып кайту, бару; кереп чыгу; *посетить знакомых* — таныш-белешләргә кереп чыгу; *посетить Кавказ* — Кавказга барып кайту; 2. *перен.* килү, төшү; *поэта посетило вдохновение* — шагыйрьгә илһам килде; *горе посетило меня* — башыма кайгы төште.

**ПОСЕ'ТОВАТЬ** *сов. книж.* — бераз зарлану, бераз сукрану.

**ПОСЕ'ЧЬ** *сов.* — 1. *разг.* (*высечь розгами*) суктыру; 2. *устар.* (*зарубить*) чабып үтерү; 3. бераз вакытны чабып үткәрү (мәс., чыбык-чабык); 4. бераз суктырып алу.

**ПОСЕЩА'ЕМОСТЬ** *ж. книж.* — йөреш; *посещаемость школы* — мәктәпкә йөреш.

**ПОСЕЩ'АТЬ** *несов.* — йөрү, бару; *посещать школу* — мәктәпкә йөрү.

**ПОСЕ'ЯТЬ** *сов.* — 1. чәчү; *посеять пшеницу* — бодай чәчү; 2. *перен.* тарату; *посеять рознь* — дошманлык тарату.

**ПОСИВЕ'ТЬ** *сов.* — күксел төскә керү.

**ПОСИДЕ'ЛКИ** *ед.* нет, *обл.* — аулак өй, кич утыру, утырма; *идти на посиделки* — аулак өйгә бару.

**ПОСИДЕ'ТЬ** *сов.* — 1. бераз утыру, утырып тору, утыру; *посидел вечером на завалинке* — кичен бераз өй артында утырдым; 2. кунып тору; *орёл немного посидел и тут же на другой овин перелетел* — бөркет бераз кунып торды да шунда ук икенче эвенгә очып китте.

**ПОСИ'ДКИ** *ед.* нет, *обл.* — к. посиделки.

**ПОСИ'ЖИВАТЬ** *несов. разг.* — утырып тору; *дед любил посиживать на солнышке* — бабай кояшта утырып торырга ярата иде.

**ПОСИ'ЛЬНЫЙ** *книж.* — кулдан килгән кадәр, көче җитәрлек, кулдан килерлек, булдыра алырлык, хәл кадәренчә, хәлдән килгәнчә, көченә күрә; *оказать посильную помощь* — кулдан килгән кадәр ярдәм итү.

**ПОСИНЕ'ЛЫЙ** *разг.* — күгәреп беткән, күгәренгән; *посинелое лицо* — күгәренгән йөз.

**ПОСИНЕ'ТЬ** *сов.* — күгәрү, күгәрену; *посинеть от холода* — суыктан күгәрену.

**ПОСКА'БЛИВАТЬ** *несов.* — бераз кыргалау, кыргалаштыру.

**ПОСКАКА'ТЬ** *сов.* — 1. бераз сикергәләп йөрү; *поскакать на одной ноге* — сыңар аяклап бераз сикергәләп йөрү; 2. (атка атланып) чабып китү; 3. бераз чабып йөрү; *поскакать верхом по полям* — атка атланып кырларда бераз чабып йөрү.

**ПОСКА'ЛЬЗЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. поскользнуться.

**ПОСКА'ЧКА** *ж. охот.* — бурзай этнең йөгерүе.

**ПОСКИТА'ТЬСЯ** *сов.* — ил гизү, дөнья гизү, бер җирдән икенче җиргә күчеп йөрү; *поскитался по свету немало* — дөньяны аз гизмәдем.

**ПОСКЛИЗНУ'ТЬСЯ** *сов. обл.* — к. поскользнуться.

**ПОСКОБЛИ'ТЬ** *сов.* — әзрәк кыру, бераз кыру, кырып алу, өстеннән кырып алу.

**ПОСКО'К** *м. спорт.* — сикерү, ыргу.

**ПОСКОЛЬЗНУ'ТЬСЯ** *сов.* — таеп китү; *поскользнуться на льду* — бозда таеп китү.

**ПОСКО'ЛЬКУ** *союз книж.* — сәбәпле; ...-гач, ...-лыктан, булган өчен; икән; *поскольку ты согласен, я не возражаю* — син риза булгач, мин дә каршы түгел.

**ПОСКО'НИНА** *ж. мн.* нет, *обл.* — баса киндере (баса сусеннән сугылган киндер).

**ПОСКО'ННЫЙ** — баса киндереннән тегелгән; *посконная рубашка* — баса киндереннән тегелгән күлмәк.

**ПО'СКОНЬ** *ж. мн.* нет, *обл. бот.* — баса, киндер басасы.

**ПОСКО'ТИНА** *ж обл.* — 1. көтүлек, мал көтә торган урын; 2. (*изгородь вокруг выгона*) көтүлек киртәсе.

**ПОСКРЁБКИ** *м.* — кырынды, касмак, кырындык, калдык-постык.

**ПОСКРЁБЫШ** *м. обл.* — кырындыктан пешерелгән икмәк, калдык-постык оннан пешерелгән икмәк.

**ПОСКРЕСТИ'** *сов.* — бераз кыру.

**ПОСКРЕСТИ'СЬ** *сов.* — бераз кыштырдап алу, тырнашып алу; *мышь поскреблась в подполье* — идән астында тычкан бераз кыштырдап алды.

**ПОСКРИПЕ'ТЬ** *сов.* — бераз шыгырдап тору.

**ПОСКРИ'ПЫВАТЬ** *несов.* — 1. азрак шыгырдау, сирәк-мирәк шыгырдап кую, вакыт-вакыт шыгырдап кую; 2. черелдәү; *кузнечик поскрипывает* — чикерткә черелди.

**ПОСКУПИ'ТЬСЯ** *сов.* — саранлану, саранлык күрсәтү.

**ПОСКУЧА'ТЬ** *сов.* — сагыну, (бераз) сагынып тору, юксынып алу; *поскучать два дня* — ике көн юксынып тору.

**ПОСЛАБЕ'ТЬ** *сов. разг.* — хәлсезләнеп китү, көчсезләнеп китү; *послабеть после болезни* — авырудан соң хәлсезләнеп китү.

**ПОСЛА'БИТЬ** *сов. безл. разг.* — эче китә башлау, эче йомшарып китү; *ребёнка послабило* — баланың эче йомшарып китте.

**ПОСЛАБЛЕ'НИЕ** *ср. книж.* — йомшаклык, узындыру; *не допускать послаблений* — йомшаклык күрсәтмәскә.

**ПОСЛАБЛЯ'ТЬ** *несов.* — 1. йомшаклык күрсәтү, ирек кую, узындыра башлау; 2. *мед.* эчне җибәрү, эчне йомшарту.

**ПОСЛА'НЕЦ** *м. книж.* — илче, вәкил; *посланцы народа* — халык илчеләре.

**ПОСЛА'НИЕ** *ср. книж.* — 1. хат, язма мөрәҗәгать; *я получил твое послание* — мин синең хатыңны алдым; 2. мөрәҗәгать (мөрәҗәгать формасында язылган әдәби әсәр).

**ПОСЛА'ННИК** *м.* — 1. посланник (илчедән бер дәрәҗәгә түбән булган дипломатик вәкил); 2. *истор. поэт.* илче, вәкил.

**ПОСЛА'ТЬ** *сов.* — җибәрү; *послать письмо* — хат җибәрү; *послать привет* — сәлам җибәрү; *послать пулю в спину* — аркасына пуля җибәрү. ◇ **Послать камень вдогонку** — арттан таш ыргытып калу. **Послать к чорту** — тиргәп җибәрү. **Чем бог послал** — хәзинәдә барынча.

**ПО'СЛЕ** — 1. *нареч.* соңыннан, соңрак; *поговорим после* — соңыннан сөйләшербез; 2. *предлог с род. п.* ...-дан соң; *после работы* — эштән соң.

**ПОСЛЕВОЕ'ННЫЙ** — сугыштан соңгы.

**ПОСЛЕ'Д** *м.* — соңгылык; чүп (мәс., сыерның бозаулаганнан соң сала торган чүбе).

**ПОСЛЕДЕ'ЙСТВИЕ** *ср. мн.* нет, *физ. спец.* — нәтиҗә, тәэсир; *последействие удобрений на почву* — туфракка ашлама кертүнең нәтиҗәсе.

**ПОСЛЕДИ'ТЬ** *сов.* — күзәтеп тору; *последить за детьми* — балаларны күзәтеп тору.

**ПОСЛЕ'ДКИ** *ед.* нет, *разг.* — калдык, калдык-постык, актык; *супу не осталось: он последки доел* — аш калмады: ул калдыгын да ашап бетергән.

**ПОСЛЕ'ДНИЙ** — 1. соңгы, ахыргы, актыккы, азакки; *последний дом на улице* — урамның азаккы өе; *последний день месяца* — айның актыккы көне; *последнее*

*слово* — соңгы сүз; 2. иң кечкенә, төпчек; *последний сын* — төпчек улы; 3. соңгы, яңа; *последняя мода* — соңгы мода; *последнее техническое усовершенствование* — яңа техник камилләштерү; 4. (*плохой*) иң начар, актыккы; 5. (*о бранных словах*) иң әшәке; *изругать последними словами* — иң әшәке сүзләр белән тиргәү; 6. иң соңгы, иң югары; *последняя степень совершенства* — камиллекнең иң югары дәрәҗәсе; 7. (*этот, только что упомянутый*) соңгысы, әйтеп кителгән. ◇ **До последнего** *разг.* — актык чиккә кадәр. **Последние времена настали** *разг. устар.* — бик авыр вакытлар килде. **В последнем счёте** — нәтиҗәдә, актык чиктә. **Отдать последний долг.** — к. долг I. **Он последняя спица в колеснице** — аның әһәмияте бик кечкенә.

**ПОСЛЕ'ДОВАТЕЛЬ** *м. книж.* — иярүче, иярчен, юлыннан (эзеннән) баручы, дәвам иттерүче (берәр тәгълиматны яклаучы һәм тормышка ашыручы).

**ПОСЛЕ'ДОВАТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн. нет* — эзлеклелек.

**ПОСЛЕ'ДОВАТЕЛЬНЫЙ** — 1. бер-бер артлы; *последовательная смена времён года* — ел вакытларының бер-бер артлы алмашынып торуы; 2. *книж.* эзлекле, төпле; *последовательный вывод* — эзлекле нәтиҗә.

**ПОСЛЕ'ДОВАТЬ** *сов. книж.* — 1. (*пойти, поехать вслед*) иярү, артыннан бару; 2. *перен.* үрнәк алу, иярү; *последуйте моему примеру* — миннән үрнәк алыгыз; 3. булу, килеп чыгу; *ответа не последовало* — җавап булмады.

**ПОСЛЕ'ДСТВИЕ** *ср. книж.* — нәтиҗә; *последствия болезни* — авыруның нәтиҗәләре. ◇ **Оставить без последствий** *офиц.* — игътибарсыз калдыру, нәтиҗәсез калдыру.

**ПОСЛЕ'ДУЮЩИЙ** *книж.* — шуннан соңгы; *в последующие годы* — шуннан соңгы елларда. ◇ **Последующие члены пропорции** *мат.* — пропорциянең икенче һәм дүртенче буыннары.

**ПОСЛЕ'ДЫШ** *м. простореч.* — 1. соңгы бала, төпчек бала; 2. *перен. презрит.* соңгы иярчен; *последыш идеализма* — идеализмның соңгы иярчене.

**ПОСЛЕ'ЖИВАТЬ** *несов. разг.* — вакыт-вакыт караштыргалау, вакыт-вакыт күз-колак булу, күз колак булгалау.

**ПОСЛЕЗА'ВТРА** *нареч.* — берсекөнгә; *деньги нужны мне будут послезавтра* — акча миңа берсекөнгә кирәк булыр.

**ПОСЛЕЗА'ВТРАШНИЙ** *разг.* — берсекөнге; *послезавтрашний вечер проведу дома* — берсекөнге кичне өйдә үткәрермен.

**ПОСЛЕЛО'Г** *м. лингв.* — бәйлек.

**ПОСЛЕОБЕ'ДЕННЫЙ** — төштән соңгы, обедтан соңгы; төшке аштан соңгы.

**ПОСЛЕОКТЯ'БРЬСКИЙ** — Октябрьдан соңгы, Октябрь революциясеннән соңгы.

**ПОСЛЕРЕВОЛЮЦИО'ННЫЙ** — революциядән соңгы.

**ПОСЛЕРОДОВО'Й** — бала китергәннән соңгы, бәбиләгәннән соңгы.

**ПОСЛЕСЛО'ВИЕ** *ср. книж.* — ахыргы сүз, соңгы сүз (китапта).

**ПОСЛО'ВИЦА** *ж.* — мәкаль. ◇ **Войти в пословицу** — мәкаль булып китү, мәкальгә әйләнеп китү, мәкальгә керү.

**ПОСЛО'ВИЧНЫЙ** — мәкаль...-ы, мәкальләр...-ы; *пословичный стиль* — мәкальләр стиле.

**ПОСЛО'ВНЫЙ** *спец.* — һәр сүз исәбеннән..., һәр сүз өчен..., сүз башыннан исәпләнә торган; *пословная оплата телеграмм* — телеграммаларга һәр сүз исәбеннән түләү, телеграмма җибәргән өчен һәр сүз исәбеннән түләү.

**ПОСЛУЖИ'ТЬ** *сов.* — (берникадәр вакыт) хезмәт итү; *он послужил три года* — ул өч ел хезмәт итте. ◇ **Это послужило причиной неудачи** — бу хәл уңышсызлыкка сәбәп булды.

**ПОСЛУЖНО'Й: послужной список** — хәрби хезмәт дәфтәре (берәр кешенең хәрби хезмәтне ничек үтәве турында барлык мәгълүматлар язылып барыла торган аерым формадагы дәфтәр).

**ПО'СЛУХ** *м. старин.* — шаһит, таныл.

**ПОСЛУША'НИЕ** *ср. только ед. книж.* — буйсыну, сүз тыңлау, әйткәнне тыңлау; *послушание родителям* — ата-анасына буйсыну.

**ПОСЛУ'ШАТЬ** *сов.* — 1. тыңлау, тыңлап тору, бераз тыңлап тору; *ваши речи послушала, теперь слушайте моих* (*А. Островский*) — мин сезнең сүзләрегезне тыңлап тордым, хәзер мине тыңлагыз инде; 2. сүзен тыңлау, киңәшен тоту; *послушать отца* — атаның сүзен тыңлау. ◇ **Послушай-ка, дружище!** — кара әле, дускай!

**ПОСЛУ'ШАТЬСЯ** *сов.* — тыңлау, буйсыну; *не послушался я умного совету* (*Крылов*) — акыллы киңәшне тыңламаган идем мин.

**ПОСЛУ'ШИВАТЬ** *несов. разг. фам.* — вакыт-вакыт тыңлау, тыңлаштыргалау.

**ПОСЛУ'ШЛИВЫЙ** *устар.* — к. послушный.

**ПО'СЛУШНИК** *м. церк.* — послушник (монастырьда торып монах булырга хәзерләнүче кеше).

**ПО'СЛУШНИЦА** *ж. церк.* — к. послушник.

**ПОСЛУ'ШНЫЙ** — тыңлаучан, күндәм, буйсынучан; *послушный ребёнок* — тыңлаучан бала.

**ПОСЛЫ'ШАТЬ** *сов. устар.* — 1. (*услышать*) ишетү; 2. (*почуять*) сизү.

**ПОСЛЫ'ШАТЬСЯ** *сов.* — ишетелү; *послышался внезапный свист* — кинәт сызгырган тавыш ишетелде.

**ПОСЛЮНИ'ТЬ** *сов.* — бераз селәгәйләү, бераз төкерекләү.

**ПОСМАКОВА'ТЬ** *сов.* — тәмләп...-у, тәмен белеп...-у; зәвыкланып...-у; *посмаковать конфеты* — тәмләп конфет ашау.

**ПОСМА'ТРИВАТЬ** *несов.* — вакыт-вакыт карау, карап алгалау, күз салгалау, караштыргалау; *посматривать на часы* — сәгатькә карап алгалау.

**ПОСМЕ'ИВАТЬСЯ** *несов.* — көлеп-көлеп

кую, көлгәләү, сиздермичә мыскыл итеп көлү.

**ПОСМЕКА'ТЬ** *сов. обл.*— уйлап карау (төшенергә тырышып); *посмекай, как нам быть* — уйлап кара, нишләргә кирәк безгә.

**ПОСМЕЛЕ'ТЬ** *сов. разг.*— кыюланып китү, батыраеп китү; *он посмелел, когда ближе познакомился с нами* — безнең белән якынрак танышкач, ул кыюланып китте.

**ПОСМЕ'ННО** *нареч.*— алмашлап, сменалап; *работают посменно* — сменалап эшлиләр.

**ПОСМЕ'ННЫЙ** — алмашлы, сменалы, смена белән..., алмаш; *посменное дежурство* — сменалы дежурство.

**ПОСМЕ'РТНЫЙ** — үлгәннән соңгы, үлгәннән соң...-ган, үлгәч...-ган; *посмертное издание* — авторы үлгәч басылган китап.

**ПОСМЕ'ТЬ** *сов.*— кыюлык җитү, батырчылык итү; *перечить не посмел я* — каршы эндәшергә кыюлыгым җитмәде. ◇ **Только посмей его тронуть** — тиеп кенә кара аңа.

**ПОСМЕШИ'ТЬ** *сов.*— көлдерү, көлдереп алу.

**ПОСМЕ'ШИЩЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— әдәм көлкесе, әдәм мәсхәрәсе; *делать из себя посмешище* — үзеңне әдәм көлкесе ясау.

**ПОСМЕЯ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж. устар.*— көлке; *предать посмеянию* — көлкегә калдыру.

**ПОСМЕЯ'ТЬСЯ** *сов.*— **1.** (*провести некоторое время весело, смеясь*) бераз көлеп алу, көлү; **2.** *устар.* көлеп карау, көлү; *посмеяться чужой беде* — кеше бәхетсезлегеннән көлү, кеше хәсрәтенә көлеп карау, кеше кайгысына көлеп карау.

**ПОСМОТРЕ'ТЬ** *сов.*— **1.** карап алу, карау; *посмотреть картину* — картина карау; **2.** (*только с отриц., не задуматься, не остановиться*) уйлап та тормау, карап та тормау. ◇ **Посмотрю, посмотрим** — уйлармын (уйларбыз), уйлап карармын (уйлап карарбыз), карап карармын (карап карарбыз).

**ПОСМОТРЕ'ТЬСЯ** *сов.*: **посмотреться в зеркало** — (үз-үзеңне) көзгедән карау.

**ПОСНЕ'ДА'ТЬ** *сов. обл.*— ашап алу, тамак ялгап алу.

**ПОСНИМА'ТЬ** *сов. разг.*— алу, алып бетерү; *поснимали все картины со стен* — стеналардан барлык картиналарны алып бетергәннәр.

**ПОСО'БИЕ** *ср.*— **1.** ярдәм, пособие; *пособия многодетным матерям* — күп балалы аналарга бирелә торган пособиеләр; **2.** (*учебник*) дәреслек, кулланма. ◇ **Наглядные пособия** — күрсәтмә әсбаплар.

**ПОСОБИ'ТЬ** *сов. простореч.*— булышу, ярдәм итү, булышлык күрсәтү.

**ПОСОБЛЯ'ТЬ** *несов. простореч.*— к. пособить.

**ПОСО'БНИК** *м.*, **ПОСО'БНИЦА** *ж.*— булышчы, булышучы, катнашучы, астыртын булышлык күрсәтүче (гадәттә начар эштә, җинаять эшләүдә).

**ПОСО'БНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.*— астыртын булышлык күрсәтү, булышлык, булышчылык, ярдәм биреп тору (җинаять эшләүдә).

**ПОСОВА'ТЬ** *сов. разг.*— тыккалау, тыккалап бетерү; *посовал деньги по карманам* — акчаларын кесәләренә тыккалап бетергән.

**ПОСО'ВЕСТИТЬСЯ** *сов.*— оялу, тартыну, кыенсыну.

**ПОСОВЕ'ТОВАТЬ** *сов.*— киңәш бирү.

**ПОСОВЕ'ТОВАТЬСЯ** *сов.*— киңәшләшү, киңәш итү; *когда ты успокоишься, мы посоветуемся* — син тынычлангач, киңәш итәрбез.

**ПОСОДЕ'ЙСТВОВАТЬ** *сов.*— бераз ярдәм итү, булышу, бераз булышлык күрсәтү.

**ПОСО'Л I** *м.*— посол, илче (югары дәрәҗәдәге дипломатик вәкил).

**ПОСО'Л II** *м.*— **1.** (*действие*) к. посолить; **2.** к. засол.

**ПОСОЛИ'ТЬ** *сов.*— тозлау, тоз салу, тоз сибү; *посолить корку хлеба* — икмәк катысына тоз сибү.

**ПОСОЛОВЕ'ЛЫЙ** *разг.*— (исерүдән яки арудан) тонган, пыялаланган (күзләр турында әйтелә).

**ПОСОЛОВЕ'ТЬ** *сов. разг.*— йокы басу, тону; *глаза его посоловели* — аның күзләре тонган.

**ПО'СОЛОНЬ** *нареч. устар.*— көнчыгыштан көнбатышка таба; *хождение посолонь* — көнчыгыштан көнбатышка таба бару.

**ПОСО'ЛЬСКИЙ** — посол...-ы, илче...-ы; *посольский автомобиль* — илче автомобиле. ◇ **Посольский приказ** *истор.*— Посольский приказ (Москва Русенда тышкы эшләр ведомствосы).

**ПОСО'ЛЬСТВО** *ср.*— **1.** посольство, илчелек; **2.** посольство урнашкан йорт; **3.** *разг. шутл.* (*люди, посланные кем-н.*) илчеләр, вәкилләр.

**ПОСОСА'ТЬ** *сов.*— суырып алу, бераз суырып алу; *пососать конфету* — бераз конфет суырып алу.

**ПО'СОХ** *м.*— таяк, чукмарлы таяк, кәкре башлы таяк (йөргәндә таяну өчен).

**ПОСО'ХНУТЬ** *сов.*— **1.** корып бетү, кибеп бетү; *цветы посохли* — чәчәкләр корып беткәннәр; **2.** кибү; *бельё посохло* — кер кипкән.

**ПОСОШКО'ВЫЙ: посошковая чарка** — юл аягына (юлга чыгар алдыннан) эчелә торган соңгы рюмка аракы.

**ПОСОШО'К** *м.*— **1.** к. посох; **2.** *разг. шутл.* юл бокалы (юлга чыгар алдыннан эчелә торган соңгы рюмка аракы).

**ПОСПА'СТЬ** *сов. разг.*— **1.** сүрелү, кимү; *жара поспала* — көннең кызулыгы кимеде, көн сүрелде; **2.** ябыга төшү, сулу; *поспала с лица* — йөзе сулган.

**ПОСПА'ТЬ** *сов.*— йоклап алу; *поспать с часок* — берәр сәгать йоклап алу.

**ПОСПЕВА'ТЬ** *несов.*— к. поспеть.

**ПОСПЕКТА'КЛЬНЫЙ** *театр.*— һәр спектакль исәбеннән...; *поспектакльная оплата* — һәр спектакль исәбеннән түләү.

**ПОСПЕ'ТЬ** *сов.*— **1.** пешү, җитү, җитлегү, өлгерү; *яблоки поспели* — алмалар пешкән; **2.** пешеп җитү, өлгерү; *обед давно поспел* — аш күптән өлгергән; **3.** өлгерү, соңга калмау; *поспеть на поезд* — поездга өлгерү.

**ПОСПЕША'ТЬ** *несов. устар.*— ашыгу, кабалану.

**ПОСПЕШЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *церк. книж. устар.*— уңыш; *желаю поспешения в делах* — эшләреңдә уңышлар телим.

**ПОСПЕ'ШЕСТВОВАТЬ** *несов. церк.-книж. устар.*— ярдәм итү, булышу.

**ПОСПЕШИ'ТЬ** *сов.*— ашыгу, кабалану. ◇ **Поспешишь — людей насмешишь** — ашыккан ашка пешкән.

**ПОСПЕ'ШНОСТЬ** *ж. мн.* нет — ашыгычлык.

**ПОСПЕ'ШНЫЙ** — ашыгыч, ашыгып...-ган; *поспешный отъезд* — ашыгып китү; *поспешное решение* — ашыгып чыгарылган карар.

**ПОСПЛЕ'ТНИЧАТЬ** *сов.*— гайбәт чәйнәү, гайбәт сату; *бабка любила посплетничать* — әби гайбәт сатарга ярата иде.

**ПОСПО'РИТЬ** *сов.*— 1. бәхәсләшү, бәхәсләшеп алу, сүз көрәштерү, сүз көрәштереп алу; *поспорили из-за пустяков* — бер дә юк нәрсә өчен сүз көрәштердек; 2. (әйбер куеп) бәхәсләшү; 3. (*вступить в состязание, в борьбу*) сынашып карау, көч сынап карау.

**ПОСПОСО'БСТВОВАТЬ** *сов.*— ярдәм итү, булышу, булышлык күрсәтү, берникадәр ярдәм күрсәтү.

**ПОСПРА'ШИВАТЬ** *несов. разг.*— к. поспросить.

**ПОСПРОСИ'ТЬ** *сов. разг.*— сораштырып белергә тырышу, сораштыргалап карау.

**ПОСПРОША'ТЬ** *сов.* и *несов. просторе́ч.*— к. поспросить.

**ПОСРАМИ'ТЬ** *сов.* — 1. *книж. ритор.* (*опозорить*) хурлыкка калдыру, оятка калдыру, оятлы итү, хур итү; 2. *книж. ритор.* (*обличить, подвергнуть осмеянию*) фаш итү, йөзен ачу, көлкегә калдыру; 3. *несов.* нет, *разг.* (*постыдить*) оялту, гарьләндерү.

**ПОСРАМИ'ТЬСЯ** *сов. книж. ритор.*— хур булу, әләм мәсхәрәсе булу, оятка калу.

**ПОСРАМЛЯ'ТЬ** *несов. книж. ритор.*— к. посрамить 1.

**ПОСРАМЛЯ'ТЬСЯ** *несов. книж. ритор.*— 1. к. посрамиться; 2. *страд.* хур ителү, оятка калдырылу.

**ПОСРЕДИ'** — 1. *нареч.* уртада; 2. *предлог с род. п.* уртасында; *посреди реки* — елга уртасында; *посреди толпы* — халык төркеме уртасында.

**ПОСРЕДИ'НЕ** *нареч.* и *предл. с род. п.*— к. посреди.

**ПОСРЕ'ДНИК** *м.*— 1. арадашчы, арадашлык итүче, маклер; 2. *воен.* судья, арбитр (хәрби манёврларда). ◇ **Мировой посредник** *истор.*— мировой посредник (1861 нче елгы реформадан соң крестьяннар белән алпавытлар арасында җир турында булган бәхәсле мәсьәләләрне хәл итү өчен дворяннар арасыннан билгеләнгән вәкил).

**ПОСРЕ'ДНИЦА** *ж.*— к. посредник 1.

**ПОСРЕ'ДНИЧАТЬ** *несов. разг.* — арадашчы булу, арадашлык итү, маклер булу.

**ПОСРЕ'ДНИЧЕСКИЙ** — арадашлык...-ы; арадашчылык...-ы; *посредническая деятельность* — арадашчылык эше.

**ПОСРЕ'ДНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет — 1. арадашлык, арадашчылык, арадашлык итү, арадашчылык итү; килештерүчелек эшләре, яраштыручылык эшләре; 2. *юр.* җинаять эшләүгә ярдәм итү.

**ПОСРЕ'ДСТВЕННО** — 1. *нареч.* уртача; *он играет посредственно* — ул уртача уйный; 2. *ср. сущ.* (*школьная отметка*) уртача, урта билгесе; *отвечал на посредственно* — урта билгесенә җавап бирде.

**ПОСРЕ'ДСТВЕННЫЙ** —уртача, канәгатьләнерлек; *посредственные способности* — уртача сәләтлелек.

**ПОСРЕ'ДСТВО** *ср. мн.* нет: **при посредстве, через посредство** — ярдәмендә, ярдәме белән, аркылы; *при посредстве друзей* — дуслар аркылы.

**ПОСРЕ'ДСТВОМ** *предлог с род. п.* — ярдәмендә, аркылы, кулланып; *посредством микроскопа* — микроскоп ярдәмендә.

**ПОСРЕ'ДСТВУЮЩИЙ** *книж.* — арадагы, аралыктагы, үзара бәйли торган, бер-берсенә бәйләү ролен үти торган; *посредствующее звено* — арадагы буын.

**ПОССО'РИТЬ** *сов.* — араларын бозу, талаштыру, ызгыштыру; *поссорить старых друзей* — иске дусларны ызгыштыру.

**ПОССО'РИТЬСЯ** *сов.* — 1. ызгышу, талашу, ачуланышу, бозылышу; 2. ызгышып тору, талашып тору, ачуланышып тору, бозылышып тору; *они не мало-таки поссорились между собой* — алар бик күп ызгышып тордылар инде.

**ПОСТ I** *м.* — 1. пост, җаваплы урын; 2. *воен. спец.* пост (берәр әйберне саклау өчен куелган кеше яки кешеләр группасы; каравыллау урыны); *стоять на посту* — постта тору; 3. *ж.-д.* кечкенә ярдәмче станция. ◇ **Умереть на посту** — постта үлү (үзенең өстенә йөкләнгән вазифаларны үтәгән вакытта үлү).

**ПОСТ II** *м.* — 1. *церк.* ураза (христианнарда); 2. *перен. разг. шутл.* тыелып тору, тыелу.

**ПОСТА'В** *м.* — 1. бер пар тегермән ташы; *мельница о двух поставах* — ике (пар) ташлы тегермән; 2. *воен. спорт.* торыш, тоту рәвеше; 3. *обл.* стан, киндер сугу станы.

**ПОСТАВЕ'Ц** *м. устар. обл.* — 1. табаклык, савыт-саба шкафы; 2. *старин.* квас кувшины.

**ПОСТА'ВИТЬ** *сов.* — кую, утырту, салу; *поставить дом* — йорт салу; *поставить парус* — җилкән кую. ◇ **Поставить в палки** *устар.*— таяк белән кыйнау.

**ПОСТА'ВКА** *ж. торг. спец.*— поставка, тәэмин итү, китерү, товар җибәреп тору; *договор на поставку дров* — утын белән тәэмин итү турында договор.

**ПОСТАВЛЯ'ТЬ** *несов.*— китереп тору, тәэмин итү, товар җибәреп тору.

**ПОСТАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— китерелү, тәэмин ителү, товар җибәрелеп тору.

**ПОСТАВЩИ'К** *м.*, **ПОСТАВЩИ'ЦА** *ж.*— поставщик, тәэмин итеп торучы; *поставщик строительных материалов* — төзү материаллары белән тәэмин итеп торучы.

**ПОСТА'ИВАТЬ** *несов. разг.*— вакыт-вакыт басып тору, басып торгалаштыру.
**ПОСТАМЕ'НТ** *м.*— 1. *архит.* постамент (һәйкәлнең, колоннаның, статуяның нигезе); 2. *тех.* төп, нигез, аслык.
**ПОСТАНА'ВЛИВАТЬ** *несов. разг.*— к. постановить.
**ПОСТАНА'ВЛИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*—к. постановляться.
**ПОСТАНО'В** *м. мн.* нет, *спорт. спец.*— к. постановка 3.
**ПОСТАНОВИ'ТЬ** *сов.*— карар чыгару; *постановить на собрании* — җыелышта карар чыгару.
**ПОСТАНО'ВКА** *ж.*— 1. *только ед.* куелыш; *постановка вопроса* — мәсьәләнең куелышы; 2. *театр.* спектакль, постановка; *новая постановка* — яңа постановка; 3. *спорт.* тотыш, торыш; *постановка корпуса при беге* — йөгергәндә гәүдәнең торышы. ◇ **Постановка голоса** — тавышның эшкәртелеше, тавышны кую.
**ПОСТАНОВЛЕ'НИЕ** *ср.*— карар.
**ПОСТАНОВЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. постановить.
**ПОСТАНОВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— карар чыгарылу.
**ПОСТАНО'ВОЧНЫЙ** *театр.*— 1. сәхнәдә кую өчен яраклы; *постановочная пьеса* — сәхнәгә кую өчен яраклы пьеса; 2. сәхнәдә кулланыла торган; *постановочные аксессуары* — сәхнәдә кулланыла торган җиһазлар.
**ПОСТАНО'ВЩИК** *м. театр. кино* — сәхнәгә куючы, куючы; *постановщик фильма* — фильмны куючы.
**ПОСТА'НЫВАТЬ** *несов. разг.* — вакыт-вакыт ыңгырашып кую, аз-маз ыңгырашу.
**ПОСТАРА'ТЬСЯ** *сов.*—тырышу, тырышып карау.◇ **Кто-то постарался начертить на обоях** — кемнеңдер кулы кычытып обойларны сызгалап бетергән.
**ПОСТАРЕ'ТЬ** *сов.*— картаю, картаеп китү.
**ПОСТАТЕ'ЙНЫЙ** *книж.* — статьялап..., һәр статьясын аерым, һәрбер статьяга карата төзелгән; *постатейный комментарий* — һәрбер статьяга карата төзелгән комментарий.
**ПОСТА'ЯТЬ** *сов. разг.*— акрынлап эреп бетү; *снег по дорогам постаял* — юллардагы карлар акрынлап эреп беткән.
**ПОСТЕГА'ТЬ** *сов.*— 1. сыдырып алу, сыптырып алу; *постегать лошадь* — атка бераз сыптырып алу; 2. сырып алу; *постегать одеяло* — юрган сырып алу.
**ПОСТЁГИВАТЬ** *несов. разг.*—1. суккалаштыру, сыдыргалаштыру; *постёгивать лошадей* — атларга сыдыргалаштыру; 2. *(заниматься стёжкой)* сыру, сыргалаштыру.
**ПОСТЕЛИ'ТЬ** *сов. простореч.*— к. постлать.
**ПОСТЕЛИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.*— к. постлаться.
**ПОСТЕ'ЛЬ** *ж.*— 1. постель, урын-җир, йоклау урыны, яту урыны, ятак; 2. *спец.* елга үзәге; 3. *горн.* файдалы казылма яткан токым; 4. *спец., тех.* нигез, аслык.
**ПОСТЕ'ЛЬКА** *ж.* — к. постель.
**ПОСТЕ'ЛЬНИК** *м.*— көрпә тышы, түшәк тышы.
**ПОСТЕ'ЛЬНИЧИЙ** *м. истор.*— постельничий (Мәскәү русенда сарай хезмәтчесе).
**ПОСТЕ'ЛЬНЫЙ** — 1. постель...-ы, яту урыны...-ы; *постельные принадлежности* — постель кирәк-яраклары; 2. *разг. фам. неодобр. перен.* женси мөнәсәбәтләргә бәйләнгән; *драма постельного содержания* — женси мөнәсәбәтләргә бәйләнгән драма. ◇ **Постельный режим** — (авырган вакытта) урында яту режимы. **Постельное бельё** — урын-җир бельёсы (мендәр тышы, җәймә һ. б.).
**ПОСТЕПЕ'ННО** *нареч.*— аз-азлап, акрынлап, бер-бер артлы, әзлекле рәвештә.
**ПОСТЕПЕ'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет — тиземлелек, кинәт үзгәрми торган булу; *постепенность развития* — үсешнең тиземлелеге; *постепенность перехода от лета к осени* — җәйдән көзгә күчүдә тиземлелек.
**ПОСТЕПЕ'ННЫЙ** — акрынлап кына... , акрын-акрын, акрынлык белән..., акрынлап..., тиземле; *постепенное выздоровление* — акрынлап терелү.
**ПОСТЕПЕ'НОВЕЦ** *м. пренебр. устар.*— постепеновчы (революцион үзгәрешләр кертүгә каршы, акрынлап үзгәртү тәгълиматы яклы кеше).
**ПОСТЕПЕ'НОВЩИНА** *ж. мн.* нет, *публиц. пренебр. устар.*— постепеновчылык (кискен революцион методларны инкарь итү).
**ПОСТЕРЕ'ЧЬ** *сов*.— бераз саклап тору; бераз каравыллап тору; *постеречь цыплят* — чебиләрне бераз саклап тору.
**ПОСТЕСНИ'ТЬСЯ** *сов. чаще с отриц. устар.*— к. постесняться.
**ПОСТЕСНЯ'ТЬСЯ** *сов.*— оялу, тартыну, кыенсыну.
**ПОСТИГА'ТЬ** *несов.*— к. постичь.
**ПОСТИ'ГНУТЬ** — к. постичь.
**ПОСТИЖИ'МЫЙ** *ср. книж.*— ирешерлек, аңларлык.
**ПОСТИЛА'ТЬ** *несов.*— җәю; *постилать постель* — урын җәю.
**ПОСТИЛА'ТЬСЯ** *несов.*— җәелү.
**ПОСТИ'ЛКА** *ж.*— 1. *только ед. (действие) к.* постлать, постилать; 2. аслык, түшәмә.
**ПОСТИ'ЛОЧНЫЙ** — түшәүлек...; *постилочная солома* — түшәүлек салам.
**ПОСТИРА'ТЬ** *сов.*— уу, бераз уып алу, юып алу; *постирать рубашку* — күлмәкне юып алу; *постирать бельё* — бераз кер уып алу.
**ПОСТИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. ураза тоту; 2. *разг. фам. (воздерживаться)* тыелып тору.
**ПОСТИ'ХНУТЬ** *сов. разг.*— акрынлап туктау, акрынлап тынычлану, акрынлап тыну.
**ПОСТИ'ЧЬ** *сов.*— 1. *(понять)* аңлау, төшенү; *не могу этого постичь* — мин моны аңлый алмыйм; 2. башка төшү; дучар булу;

*его постигло несчастье* — ул бәхетсезлеккә дучар булды.

**ПОСТЛА'ТЬ** *сов.* — җәю, түшәү, урын җәю.

**ПОСТЛА'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — урын җәю (үзенә); *я постлался на диване* — мин үземә диванга урын җәйдем.

**ПО'СТНИК** *м.*, **ПО'СТНИЦА** *ж.* — ураза тотучы.

**ПО'СТНИЧАТЬ** *несов. разг.* — к. поститься.

**ПО'СТНЫЙ** — 1. итсез; *постный обед* — итсез аш; 2. ябык; *постная телятина* — ябык бозау ите; 3. *перен.* күңелсез, боек (йөз, чырай); *постная физиономия* — күңелсез чырай. ◇ **Постное масло** — үсемлек мае. **Постные речи** *перен.* — икейөзлеләнеп сөйләгән речьләр. **Постный сахар** — җимеш суына шикәр салып ясалган конфет.

**ПОСТОВО'Й** — 1. постта торучы; *постовой милиционер* — постта торучы милиционер; 2. пост...-ы; *постовая будка* — пост будкасы.

**ПОСТО'Й** *м. мн.* нет — 1. *воен.* постой (аерым гаскәри частьларның яки аерым гаскәри хезмәткәрләрнең хосусый йортларда квартирада торуы); 2. *простореч.* (*ночёвка*) куныш чыгу.

**ПОСТО'ЛЬКУ** *союз* — шулай булгач; *поскольку решение принято, постольку его надо выполнять* — карар кабул ителгән икән, (шулай булгач) аны тормышка ашырырга кирәк.

**ПОСТОРОЖИ'ТЬ** *сов.* — к. постеречь.

**ПОСТОРОНИ'ТЬСЯ** *сов.* — юл бирү, читкә тайпылу, читкә чыгу.

**ПОСТОРО'ННИЙ** — 1. ят, чит, таныш булмаган; *посторонние люди* — чит кешеләр; 2. *книж.* чит, турыдан-туры бәйләнеше булмаган, башка; *посторонний вопрос* — башка мәсьәлә.

**ПОСТОЯ'ЛЕЦ** *м.*, **ПОСТОЯ'ЛИЦА** *ж. разг. устар.* — торучы, вакытлыча квартирада торучы.

**ПОСТОЯ'ЛЫЙ** *устар.*: **постоялый двор** — постоялый двор (атлы юлчылар кереп куна торган йорт).

**ПОСТОЯ'ННО** *нареч.* — һәрвакыт, гел, өзлексез, бертуктаусыз.

**ПОСТОЯ'ННОСТЬ** *ж., книж.* — к. постоянство.

**ПОСТОЯ'ННЫЙ** — 1. өзлексез...-а торган, туктаусыз...-а торган, даими, бертуктаусыз; *постоянные ветры* — бертуктаусыз исә торган җилләр; *постоянная работа* — даими эш; 2. көндәге, көндәлек, гади, һәрвакыт була торган; *он наш постоянный гость* — ул безнең һәрвакыт килә торган кунагыбыз; 3. үзгәрми торган, тигез, тотрыклы; *постоянный характер* — үзгәрми торган характер. ◇ **Постоянная армия** — даими армия. **Постоянная величина** *мат.* — даими зурлык. **Постоянный капитал** *экон.* — даими капитал (производство процессында кыйммәте үзгәрми торган капитал). **Постоянный ток** — даими ток (даими юнәлешле ток). **Постоянное расписание поездов** — поездларның даими расписаниесе.

**ПОСТОЯ'НСТВО** *ср. мн.* нет — 1. *науч.* (*неизменность*) үзгәрмәүчәнлек, даимилек; 2. тотрыклылык, тугрылык, тотрыклы булу, ныклык; *постоянство во взглядах* — караштa тотрыклылык, карашларның тотрыклы булуы.

**ПОСТОЯ'ТЬ** I *сов.* — басып тору, бераз басып тору; *в вагоне пришлось постоять* — вагонда басып торырга туры килде.

**ПОСТОЯ'ТЬ** II *сов.* — яклау, саклау, нык тору, һөҗүмнән саклау, һөҗүмгә каршы тору; *постоять за родину* — ватанны саклау.

**ПОСТОЯ'ТЬ** III: **постой (те)** *разг.* — 1. көт(егез), ашыкма(гыз); *постой, я сейчас приду* — көт, мин хәзер килермен; 2. тукта, карә; *постой, а ты не ошибся?* — тукта, ә син ялгышмадыңмы?

**ПОСТПАКЕ'Т** *м. спец.* — постпакет (бер үк җиргә җибәрелә торган хатлар төргәге).

**ПОСТРАДА'ТЬ** *сов.* — зарар күрү, җәфа чигү, интегү, газап чигү; *он немало пострадал от зубной боли* — теше авыртудан ул аз интекмәде (бик күп интекте).

**ПОСТРАНИ'ЧНЫЙ** *спец.* — битләп, бит саен...; *постраничный подсчёт* — битләп исәпләү; *постраничная нумерация* — бит саен нумер куеп чыгу.

**ПОСТРА'НСТВОВАТЬ** *сов.* — ил гизү, (берникадәр вакыт) ил гизеп йөрү, байтак кына дөнья гизү, бераз сәяхәт итеп йөрү.

**ПОСТРАЩА'ТЬ** *сов. простореч.* — бераз куркыту, бераз куркытып алу; *слегка постращать ребёнка* — баланы бераз куркытып кую.

**ПОСТРЕ'Л** *м. разг.* — 1. *бран.* шаян, шук малай; *наш пострел везде поспел* (*поговорка*) — безнең шук малай бар җиргә дә житешә; 2. (*прострел*) сызлау, чәнчешү (күбрәк билдә була); 3. *обл.* паралич.

**ПОСТРЕЛЁНОК** *м. разг. фам.* — к. пострел 1.

**ПОСТРЕ'ЛИВАТЬ** *несов.* — 1. вакыт-вакыт аткалау, сирәк-мирәк аткалаштыру; 2. *разг.* чәнчешү, чатнау; *постреливает в боку* — кабыргам чәнчешә; *постреливает в ухе* — колагым чатный.

**ПОСТРЕЛЯ'ТЬ** *сов.* — 1 бераз атып алу; *пострелять из ружья* — бераз мылтык атып алу; 2. *разг.* атып бетерү (күпне, барысын да); *пострелять всех уток* — барлык үрдәкләрне атып бетерү.

**ПО'СТРИГ** *м. церк.* — чәчне кистерү (монахлык кабул итү йоласы).

**ПОСТРИГА'ТЬ** *несов* — к. постричь.

**ПОСТРИГА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. постричься; 2. *страд.* чәч кыркылу.

**ПОСТРИ'ЧЬ** *сов.* — кырку, кыркыту, чәч алу, кисү; *постричь волосы* — чәч кырку; *постричь ногти* — тырнак кисү.

**ПОСТРИ'ЧЬСЯ** *сов.* — 1. (*подрезать волосы*) чәч кистерү, чәч алдыру, чәч кыркыту; 2. *церк.* монахлык кабул итү.

**ПОСТРОЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед. книж.* (*действие*) к. построить, строить;

2. *книж.* төзелеш; *построение фразы* — җөмләнең төзелеше; 3. тәгълимат, теория; *философское построение*— философик теория; 4. *воен.* (*строй, расположение в строю*) строй төзелеше, сафка тезелү, тезелеш.

**ПОСТРО'ЕЧНЫЙ** *спец.* — төзү...-ы, төзелеш...-ы; *построечный комитет* — төзелеш комитеты (төзелештә профсоюз комитеты).

**ПОСТРО'ИТЬ** *сов.* — 1. төзү, төзеп житкерү, кору, салу; *построить дом* — йорт салу; *построить новую жизнь* — яна тормыш кору; *построить коммунизм* — коммунизм төзү; 2. *воен.* сафка тезү; *построить роту* —ротаны сафка тезү.

**ПОСТРО'ИТЬСЯ** *сов.*— 1. үзенә йорт салу; *крестьянин построился около поля* — крестьян басу кырында үзенә йорт салды; 2. *воен.* сафка тезелү; *эскадрон построился* — эскадрон сафка тезелде.

**ПОСТРО'ЙКА** *ж. мн.* нет — 1. төзү, кору, салу; *постройка дома* — йорт салу; 2. төзелеш урыны; *я пошёл на постройку*— мин төзелеш урынына киттем; 3. йорт, каралты, бина; *деревянная постройка* — агач каралты.

**ПОСТРО'МКА** *ж.*— мичәү арканы, мичәү бавы, постромка (атны мичәүгә, сабанга һ. б. җиккәндә тартә хезмәтен үти торган аркан яки каеш).

**ПОСТРО'МОЧНЫЙ** — постромка...-ы; *постромочный ремень* — постромка каешы.

**ПОСТРОЧИ'ТЬ** *сов.*— каю, каеп алу, бераз каю. ◇ **Построчить из автомата** — автоматтан сиптереп алу, автоматтан бераз ут яудырып алу.

**ПОСТРО'ЧНЫЙ**—юллап..., юл саныннан.., юл исәбеннән... ; *построчная оплата* — юл саныннан түләү.

**ПОСТРЯ'ПАТЬ** *сов.*— бераз пешерү, пешерү (берникадәр вакыт); *постряпать обед* — төшкә аш пешерү.

**ПОСТСКРИ'ПТУМ** *м. книж.*—постскриптум (хат азагына кул куйганнан соң өстәп язылган язу; гадәттә бу язу алдыннан латинча P. S. хәрефләре куела).

**ПОСТУДИ'ТЬ** *сов. разг.*— бераз суыту, бераз суытып алу, бераз салкында тоту; *постудить суп* — ашны бераз суыту.

**ПОСТУ'КАТЬ** *сов.* — бераз шакылдату; *постукать в дверь* — ишекне бераз шакылдату.

**ПОСТУ'КАТЬСЯ** *сов.*— бәрелешү, бәргәләшеп алу; *бараны постукались лбами* — тәкәләр маңгайлары белән бәргәләшеп алдылар.

**ПОСТУ'КИВАТЬ** *несов.* — вакыт-вакыт шакылдату, ашыкмыйча гына шакылдату, шакылдаткалау.

**ПОСТУЛА'Т** *м. книж.*— постулат (берәр фәнни теория төзү өчен исбатланмаган яки дәлилләнмәгән булуына карамастан дөрес дип кабул ителгән чыганак-принцип).

**ПОСТУЛИ'РОВАТЬ** *сов.*— кирәк дип таләп итү, кирәк дип тану, постулат итеп билгеләү.

**ПОСТУПА'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — алга таба юнәлгән, алга бара торган, алга омтыла торган, прогрессив; *поступательное движение* — алга бара торган хәрәкәт.

**ПОСТУПА'ТЬ** *несов.*— к. поступить.

**ПОСТУПА'ТЬСЯ** *несов.*— к. поступиться.

**ПОСТУПИ'ТЬ** *сов.*—1. эшләү; *поступить правильно* — дөрес эшләү; 2. эш итү; *он поступил нечестно с чужими деньгами* — ул кеше акчасы белән намуссыз эш иткән; 3. керү; *поступить в школу* — мәктәпкә керү; 4. килү; *в суд поступила жалоба* — судка жалоба килде; 5. чыгу; *книга поступила в продажу* — китап сатылуга чыкты; 6. *офиц.* күчү; *наследство поступило в казну* — мирасы казнага күчте.

**ПОСТУПИ'ТЬСЯ** *сов.*— баш тарту, ташлау; *поступиться своими привычками из любви к кому-н.*— берәр кешене яратып үзенең гадәтләренә ташлау; *поступиться своим правом* — үз хокукыңнан баш тарту.

**ПОСТУПЛЕ'НИЕ** *ср.*— 1. *только ед.* (*действие*) к. поступить 3, 4, 5. 2. *спец.* (*деньги, доход*) керем, кергән акча, килгән доход; *поступление в сберкассу* — саклык кассасына кергән акча.

**ПОСТУ'ПОК** *ж. мн.* нет — кылыныш, эшләгән эш; *человек должен отдавать себе отчёт в своих поступках* — кеше үзе эшләгән эшләренә җаваплы булырга тиеш.

**ПО'СТУПЬ** *ж. мн.* нет — адым, атлау, аяк басуы, йөреш; *важная поступь* — мәһабәт йөреш; *неслышная поступь* — кеше ишетмәслек аяк басуы; *народы Советского Союза уверенной поступью идут к коммунизму* — Советлар Союзының халыклары ышанычлы адымнар белән коммунизмга баралар.

**ПОСТУЧА'ТЬ** *сов.*— шакылдату, шакылдатып кую.

**ПОСТУЧА'ТЬСЯ** *сов.*— шакылдату, кагу; *постучаться в дверь* — ишекне шакылдату.

**ПОСТФА'КТУМ** *нареч. книж.*— эш үткәч, эш үткәннән соң; *постфактум об этом нет смысла говорить* — эш үткәч бу турыда сөйләп торуның мәгънәсе юк.

**ПОСТЫДИ'ТЬ** *сов. разг.* — оялту, гарьләндерү, йөзен кызарту.

**ПОСТЫДИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— оялу, гарьләнү.

**ПОСТЫ'ДНЫЙ** *книж.*— оятсыз, хурлыклы, түбән; *постыдная ложь* — хурлыклы ялган.

**ПОСТЫ'ЛЕТЬ** *несов. разг.*— сөйкемсезләнү, сөйкемсез булу, туйдыру.

**ПОСТЫ'ЛЫЙ** *простореч.* — сөйкемсез, күңел кайтаргыч, туйдыргыч.

**ПОСТЫ'ТЬ** *сов. разг.*— суыну, суына төшү; *пусть чай постынет немного* — чәй бераз суынсын әле.

**ПОСУ'ДА** *ж. мн.* нет —1. *собир.* савыт-саба; *бить посуду* — савыт-саба вату; 2. *разг.* савыт; 3. *обл.* жилкәнле кечкенә судно.

**ПОСУДА'ЧИТЬ** *сов. разг.*— бераз гайбәт сатып алу, бераз сөйләшеп алу.

**ПОСУ'ДИНА** *ж. разг. фам.*— 1. савыт; 2. *обл.* судно, корабль, көймә.

**ПОСУДИ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. уйлау, уйлап карау; *сам посуди* — үзең уйлап кара; 2. судта тикшерү (берәр эшне).

**ПОСУДИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— судлашып йөрү (берникадәр вакыт).

**ПОСУ'ДНИК** *м.*— 1. *обл.* савыт-саба шкафы; 2. *спец.* савыт-саба юучы.

**ПОСУ'ДНИЦА** *ж. обл.* — савыт-саба юучы (хатын-кыз).

**ПОСУ'ДНЫЙ** — савыт-саба...-ы; *посудный магазин* — савыт-саба магазины.

**ПОСУЕТИ'ТЬСЯ** *сов.*— бераз ыгы-зыгы килеп алу, бераз кабаланып алу; *посуетился немного и успокоился* — бераз ыгы-зыгы килеп алды да тынды.

**ПОСУ'Л** *м. просторeч.*— 1. вәгъдә; *за посул денег не берут* (посл.) — вәгъдә өчен акча алмыйлар; 2. *устар.* взятка.

**ПОСУЛИ'ТЬ** *сов. просторeч.* — вәгъдә итү, ышандыру.

**ПОСУЛИ'ТЬСЯ** *сов. просторeч.* — вәгъдә бирү, вәгъдә итү; *посулился прийти, да не идёт* — килергә вәгъдә биргән иде дә, килми.

**ПОСУМАСШЕ'СТВОВАТЬ** *сов. разг.*— бераз җенләнеп алу, бераз ахмаклыклар эшләп ташлау.

**ПОСУРЬМИ'ТЬ** *сов.* — бераз сөрмә сөртү, бераз сөрмә тарту.

**ПОСУ'СЛИТЬ** *сов. просторeч.*— төкерекләү; *посуслить пальцы* — бармакларны төкерекләү.

**ПОСУ'ТОЧНЫЙ** — тәүлекләп..., тәүлекләп эшләнә торган, һәр тәүлек өчен аерым исәпләнә торган, тәүлек исәбеннән...; *посуточное дежурство* — тәүлекләп дежурить итү; *посуточная оплата* — тәүлек башыннан түләү.

**ПО'СУХУ** *нареч. разг.*— коры җирдән; *рыба посуху не ходит* (посл.) — балык коры җирдән йөрми.

**ПОСУШИ'ТЬ** *сов.*— киптерү, бераз киптереп алу; *посушить промокшее пальто* — чыланган пальтоны бераз киптереп алу.

**ПОСУШИ'ТЬСЯ** *сов.* — бераз киптерену, киптеренеп алу.

**ПОСХОДИ'ТЬ** *сов. разг. фам.*: **от радости чуть с ума не посходили** — шатлыктан аз гына акылдан язмадылар.

**ПОСЧАСТЛИ'ВИТЬСЯ** *сов.*— бәхетка туры килү, унай килү, бәхеткә ирешү, җай килү; *не посчастливилось ему попасть на премьеру в театр* — аңа театрның премьерасына керергә җай туры килмәде.

**ПОСЧИТА'ТЬ** *сов.*— 1. исәпләү, санау, санап чыгу, исәпләп чыгу; *посчитать деньги* — акчаны санап чыгу; 2. санап үткәрү (берникадәр вакыт); 3. *разг.* (... дип) белү, (... дип) уйлау; *я посчитал для себя неудобным идти к нему* — мин аның янына баруны үзем өчен уңайсыз дип уйладым.

**ПОСЧИТА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— исәпләшү, үч алу; *мы с тобой ещё посчитаемся* — без синең белән исәпләшербез әле.

**ПОСЧИ'ТЫВАТЬ** *несов. разг.*— ашыкмыйча санау, вакыт-вакыт санау, азлап-азлап санау, санаштыргалау.

**ПОСЫ'Л** *м. мн.* нет, *воен. спорт.*— ыргылдыру, җибәрү; *посыл лошади вперёд* — атны алга ыргылдыру.

**ПОСЫЛА'ТЬ** *несов.*— к. послать.

**ПОСЫЛА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. *устар.* к. послаться; 2. *страд.* җибәрелү.

**ПОСЫ'ЛКА** *ж.*— 1. *только ед. (действие)* к. послать; 2. посылка (почта аркылы җибәрелә торган яки читтән җибәрелгән әйбер); 3. *филос. книж.* (*суждение*) алшарт (нәтиҗә ясауга нигез итеп алынган фикер).◇ **Быть на посылках** — йомышка йөреп тору, йомышчы малай булып йөрү.

**ПОСЫ'ЛОЧНЫЙ** — посылкалар алу һәм җибәрү...-ы; *посылочная контора* — посылкалар алу һәм җибәрү конторасы.

**ПОСЫ'ЛЬНЫЙ** — 1. йомыш белән җибәрелә торган; *посыльное судно* — йомыш белән җибәрелә торган судно; 2. йомышка йөрүче хезмәтче; *посыльный при канцелярии* — канцеляриянең йомышка йөрүче хезмәтчесе; 3. *воен.* посыльный, йомышка йөрүче.

**ПОСЫ'ПАТЬ** *сов. разг.*— сибү; *посыпать песком дорожки* — юлларга ком сибү.

**ПОСЫПА'ТЬ** *несов.*— к. посыпать.

**ПОСЫ'ПАТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. (*начать сыпаться*) сибелә башлау, коела башлау; 2. *перен. разг.* ява башлау; *посыпались вопросы к докладчику* — докладчыга сораулар ява башлады.

**ПОСЫПА'ТЬСЯ** *несов страд.* — сибелү.

**ПОСЫХА'ТЬ** *несов.*— к. посохнуть 1.

**ПОСЯГА'ТЕЛЬСТВО** *ср. книж.*— кул сузу, хаслану; *посягательство на чужое имущество* — кеше милкенә хаслану, кеше милкенә кул сузу.

**ПОСЯГА'ТЬ** *несов. книж.*— к. посягнуть.

**ПОСЯГНУ'ТЬ** *сов.*— 1 хаслану, тукыну, (берәр нәрсәне эшләргә) омтылу; *посягнуть на жизнь* — үтерергә маташу, үтерергә омтылу; 2. үзләштерергә маташу, алырга маташу, кул сузу; *посягнуть на чужое имущество* — кеше милкен үзләштерергә маташу, кеше милкенә кул сузу.

**ПОТ** *м.*— тир. ◇ **В поте лица** — тир түгеп, кара тиргә батып (эшләү). **Пóтом и кровью** — кан һәм тир түгеп (бик күп көч куеп). **До седьмого пота** — җиде кат тирем чыкканчы; тирләп-пешеп беткәнче. **Цыганский пот пробивает** *шутл. устар.*— бик өшетә, бик суык. **Согнать семь потов** *разг.*— хәлдән тайдырганчы эшләтү, тирләтү. **Пот градом катился с него** — аңардан шыбырдап тир ага иде. **Вогнать в пот** — тиргә батыру. **Кровавый пот** — авыр эш эшләп хәлдән таю.

**ПОТАЁННЫЙ** *устар.*— к. потайной.

**ПОТАИ'ТЬ** *сов.* — 1. *разг.* яшерү, яшереп тору; 2. (берникадәр вакыт) яшереп тору, (берникадәр вакыт) сер итеп саклау.

**ПОТАИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— (берникадәр вакыт) яшеренеп тору.

**ПОТА'Й** *нареч. обл.* — яшеренеп,

яшертен. ◇ **В потай** *тех.* — өслек белән тип-тигез итеп, башы чыгып тормаслык итеп; *утопить винт в потай* — шөрепне башы чыгып тормаслык итеп борып кую.

**ПОТАЙНО'Й** — яшерен; *потайной ход* — яшерен юл.

**ПОТАКА'ТЕЛЬ** *м. разг.* — юл куючы, ирек куючы, узындыручы.

**ПОТАКА'ТЬ** *несов. разг.* — узындыру, хуплау, юл кую, ирек бирү; *потакать баловству детей* — балаларның шуклыгына юл кую.

**ПОТАКНУ'ТЬ** *сов. разг.* — к. потакать.

**ПОТАКО'ВЩИК** *м. простореч.* — к. потатчик.

**ПОТА'ЛЬ** *ж. мн.* нет, *спец.* — путал.

**ПОТА'ЛЬНЫЙ** *спец.* — путал...-ы; *потальное золото* — путал алтыны.

**ПОТАНЦЕВА'ТЬ** *сов.* — бераз танцевать итеп алу.

**ПОТА'ПЛИВАТЬ** *несов. разг.* — 1. сирәкмирәк яккалау, яккалаштыру; аз-маз яккалау; *изредка потапливать печку* — сирәкмирәк мичкә яккалау; 2. эреткәләү, сирәкмирәк эретү; *потапливать воск* — балавыз эреткәләү.

**ПОТА'ПТЫВАТЬ** *несов.* — 1. к. потоптать; 2. бераз таптанып тору.

**ПОТАСКА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. бераз ташу; *потаскать дров* — бераз утын ташу; 2. бераз тарткалау; *потаскать за волосы* — чәчләрен бераз тарткалау; 3. (*украсть*) урлау, урлап бетерү.

**ПОТАСКА'ТЬСЯ** *сов. фам. неодобр.* — йөрү, буталып йөрү; *потаскался по свету немало* — дөньяда аз буталып йөрмәдем инде.

**ПОТА'СКИВАТЬ** *несов. разг.* — алып киткәләү, урлаштыргалау; *кур потаскивают из курятника* — тавык кетәгеннән тавыкларны урлаштыргалыйлар.

**ПОТАСКУ'Н** *м.*, **ПОТАСКУ'НЬЯ** *ж. простореч. бран.* — сөйрәлчек (хатын-кыз артыннан яки ирләр артыннан күп йөрүче).

**ПОТАСКУ'ХА, ПОТАСКУ'ШКА** *ж. простореч. бран.* — сөйрәлчек (хатын-кыз), очраган бер ир белән чуала торган хатын-кыз.

**ПОТАСО'ВКА** *ж. разг.* — 1. тиргәшеп сугышу; әрләшеп кыйнашу; 2. тукмап ташлау; *задать потасовку* — тукмап ташлау; 3. *фам.* тормыш кыенлыклары, күңелсезлекләр; *вышел с честью из всех потасовок* — тормышында булган бөтен кыенлыкларны җиңеп чыкты.

**ПОТАТУ'ЙКА** *ж.* — һөд-һөд (кош).

**ПОТА'ТЧИК** *м.*, **ПОТА'ТЧИЦА** *ж. разг.* — ирек куючы, юл куючы, үзсендерүче, узындыручы.

**ПОТАЧА'ТЬ** *сов. спец. разг.* — бераз тегеп алу; *потачать сапоги* — бераз итек тегеп алу.

**ПОТА'ЧИВАТЬ** I *несов. разг.* — кайраштыргалау, чарлаштыргалау.

**ПОТА'ЧИВАТЬ** II *несов. спец. разг.* — бераз теккәләштерү.

**ПОТА'ЧКА** *ж. разг.* — юл кую, ирек кую, узындыру.

**ПОТА'Ш** *м.* — поташ (үсемлек көленнән, калий тозларыннан алына торган селтеле каты ак матдә).

**ПОТА'ШНЫЙ** — поташ...-ы; *поташное производство* — поташ производствосы.

**ПОТАЩИ'ТЬ** *сов.* — сөйрәп алып китү, өстерәп алып китү.

**ПОТАЩИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — акрынлап кына китеп бару, акрын гына китү; *старик потащился домой* — карт акрынлап кына өйгә кайтып китте.

**ПОТВЕРДЕ'ТЬ** *сов.* — бераз катып китү, ката төшү, бераз катылану.

**ПОТВО'РСТВО** *ср. устар. книж.* — (ярамаган берәр эшкә) юл кую, ирек бирү, узындыру; *потворство лентяям* — ялкауларга юл кую.

**ПОТВО'РСТВОВАТЬ** *несов. книж.* — (ярамаган эшкә) юл кую, ирек кую, узындыру.

**ПОТВО'РЩИК** *м.*, **ПОТВО'РЩИЦА** *ж.* — юл куючы, ирек куючы, узындыручы (ярамаган эшкә).

**ПОТЁМКИ** *ед.* нет — 1. караңгылык, караңгы; *сидеть в потёмках* — караңгыда утыру; 2. *перен.* билгесезлек, караңгылык. ◇ **Чужая душа—потёмки** — кешенең күңеле караңгы (кешенең күңелендә нәрсә булганы билгеле түгел).

**ПОТЕМНЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — караңгылану, караңгыланып китү, караңгы төшү; каралу.

**ПОТЕМНЕ'ТЬ** *сов.* — 1. каралу, каралып китү; кара төскә керү; *волосы потемнели* — чәчләре каралган; *серебро потемнело* — көмеш каралды; 2. караңгылану, караңгыланып китү; *в комнате потемнело* — бүлмә караңгыланды; *в глазах потемнело* — күз аллары караңгыланып китте.

**ПОТЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — к. потеть.

**ПОТЕНТА'Т** *м. истор.* — хакимлек итүче, власть иясе.

**ПОТЕНЦИА'Л** *м.* — потенциал (1. *спец.* пространствоның билгеле бер ноктасындагы энергия запасының зурлыгын характерлый торган физик төшенчә; 2. *перен.* берәр эш өчен кирәк булган барлык чараларның, шартларның бергә кушылуы).

**ПОТЕНЦИА'ЛЬНЫЙ** — 1. *тех.* потенциаль, потенциядәге, яшерен; *потенциальная энергия* — потенциаль энергия; 2. *перен.* булуы ихтимал булган (мөмкин булган); *потенциальный противник* — булуы ихтимал булган дошман.

**ПОТЕНЦИ'РОВАНИЕ** *ср. мат.* — к. потенцировать.

**ПОТЕНЦИ'РОВАТЬ** *сов. мат.* — потенцирлау (бирелгән логарифм буенча санны табу).

**ПОТЕ'НЦИЯ** *ж. мн.* нет — потенция (билгеле шартларда килеп чыгуы, хәрәкәт итүе мөмкин булган яшерен көч).

**ПОТЕПЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — к. потеплеть.

**ПОТЕПЛЕ'ТЬ** *сов.* — җылыну, җылытып җибәрү, җылына төшү, җылыта төшү; *к*

*вечеру потеплело* — кичкә таба көн жылынды, кичкә таба жылыта төште.

**ПОТЕРЕ'ТЬ** *сов.* — бераз ышку, бераз уу; *потереть спину мазью* — арканы бераз мазь белән ышку.

**ПОТЕРЕ'ТЬСЯ** *сов.* — ышкыну; *собака потёрлась о моё платье* — эт минем киемгә ышкынды.

**ПОТЕРПЕ'ТЬ** *сов.* — 1. түзү, түзеп тору, чыдау, чыдап тору, сабыр итү; *пока рвали зуб, пришлось потерпеть* — тешне алдырганда чыдап торырга туры килде; 2. *книж.* күрү, дучар булу, очрау; *потерпеть убыток* — зыян күрү; *потерпеть неудачу* — бәхетсезлеккә очрау, уңышсызлыкка очрау; 3. чыдап тору, түзеп тору, күтәрү, күтәрә алу; *не потерплю оскорблений* — мыскыл итүне күтәрә алмам.

**ПОТЁРТОСТЬ** *ж.* — 1. *только ед.* кыршылганлык, таушалганлык, искергәнлек; *потёртость пиджака* — пиджакның искергәнлеге; 2. *спец.* чиләнгәнлек, чиләнгән урын, суелганлык, суелган урын; кырылган урын *потёртости ног* — аякның кырылган урыннары.

**ПОТЕ'РЯ** — 1. югалту, югалу, югалган нәрсә; *убрать урожай без потерь* — уңышны югалтусыз жыеп алу; *враг понёс большие потери* — дошман күп югалтуларга дучар булды; *потеря документов* — документларның югалуы, документларны югалту; 2. *воен.* сафтан чыккан кешеләр, югалган кешеләр; *список потерь* — югалган кешеләрнең исемлеге. ◇ **Напрасная потеря времени** — бер дә юкка вакыт уткәрү. **Потеря сознания** — аңны югалту, һуштан язу.

**ПОТЕРЯ'ТЬ** *сов.* — югалту; *потерять голову* — башны югалту (нишләргә белмәү); *потерять доверие* — ышанычны югалту; *потерять право на что-н.* — берәр нәрсәгә хокукын югалту. ◇ **Потерять зрение** — сукраю. **Потерять время** — вакыт әрәм итү. **Потерять надежду** — өметне өзү. **Потерять в весе** — авырлыгы кимү. **Потерять силу** — көче бетү. **Потерять из виду** — күздән югалту.

**ПОТЕРЯ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. югалу; *тетрадь потерялась* — дәфтәр югалган; 2. *перен.* аптырап калу, югалып калу; *от смущения я совсем потерялся* — оялуымнан мин бөтенләй югалып калдым.

**ПОТЕСА'ТЬ** *сов.* — бераз юну; *потесать бревно* — бүрәнәне бераз юну.

**ПОТЕСНИ'ТЬ** *сов.* — кыса төшү, тыгызлый төшү; кысрыклау.

**ПОТЕСНИ'ТЬСЯ** *сов.* — кысыла төшү; тыгызлана төшү, кысылу; *потеснитесь, дайте пройти* — бераз кысыла төшегез, үтеп китәргә ирек бирегез.

**ПОТЁСЫВАТЬ** *несов. разг.* — ашыкмыйча гына юну, акрынлап кына юну.

**ПО'ТЕСЬ** *ж. спец.* — зур ишкәк (сал, баржа кебекләрнең койрык ишкәге).

**ПОТЕ'ТЬ** *несов.* — 1. тирләү, парлану, булану; *руки потеют* — куллар тирли; *окна потеют* — тәрәзәләр парлана; 2. *перен. разг. шутл.* тиргә бату, күп көч кую; тирләп-пешеп утыру; *потеть над задачей* — мәсьәлә чишү өчен күп көч кую; мәсьәлә өстендә тирләп-пешеп утыру.

**ПОТЕ'ХА** *ж.* — мәзәк, көлке, юаныч, уен-көлке.

**ПОТЕ'ЧЬ** *сов.* — 1. ага башлау, агу; *потекли ручьи* — гөрләвекләр ага башлады; 2. ага башлау, тишелү; *ведро потекло* — чиләк ага башлады, чиләк тишелде.

**ПОТЕША'ТЬ** *несов.* — бераз күңелен ачу, көлдерү, күңелен табу, юату; *потешать ребят* — балаларны көлдерү.

**ПОТЕША'ТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. күңел ачу, көлү, юану; 2. (*глумиться*) мыскыл итү, мәсхәрәләү, көлү; *потешаться над глупостью* — ахмаклыктан көлү.

**ПОТЕ'ШИТЬ** *сов.* — к. потешать.

**ПОТЕ'ШИТЬСЯ** *сов. разг.* — күңел ачу, юану.

**ПОТЕ'ШНО** *нареч. разг.* — кызыклы итеп, мәзәк итеп; *потешно рассказывает* — кызыклы итеп сөйли).

**ПОТЕ'ШНЫЙ** — кызык, мәзәк, көлке; *потешный человек* — кызык кеше, мәзәк кеше. ◇ **Потешные огни** *устар.* — фейерверк (кызык өчен ясалган утлар). ◇ **Потешные полки** *истор.* — потешный полклар (Пётр I бала вакытта аның тарафыннан Көнбатыш Европадагыча яшьләрдән оештырылган кечкенә гаскәр.

**ПОТИРА'ТЬ** *несов. разг.* — угалау, вакыт-вакыт уу; ышку; *потирать руки* — кулларны угалау; *потирать ушибленное место* — бәрелгән жирне ышку.

**ПОТИ'СКАТЬ** *сов.* — кысу, кыскалау, бераз кысу.

**ПОТИХО'НЬКУ** *нареч. разг.* — 1. әкрен генә, әкренләп, иләп кенә, ашыкмыйча гына; 2. (*тайно, по секрету*) яшертен, шыпырт кына, сиздермичә.

**ПОТКА'ТЬ** *сов.* — бераз туку, бераз сугу; *поткать холст* — бераз киндер сугу.

**ПОТЛИ'ВОСТЬ** *ж.* — тирләүчәнлек; *потливость ног* — аякның тирләүчәнлеге.

**ПОТЛИ'ВЫЙ** — тирләүчән, тирчел, тирли торган; *потливые руки* — тирли торган куллар.

**ПОТНИ'К** *м. спец.* — ияр киезе, ыңгырчак киезе.

**ПО'ТНЫЙ** — тирле, буланган, парланган, тирләгән; *потные руки* — тирле куллар; *потные стёкла окон* — парланган тәрәзә пыялалары.

**ПОТОВО'Й** — тир...-ы; *потовые железы* — тир бизләре.

**ПОТОГО'ННЫЙ** — 1. *мед.* тирләтә торган, тир чыгара торган; *потогонное средство* — тир чыгара торган дару; 2. *перен. разг.* хәлдән тайдыра торган, эксплуататорларча...; *потогонная система труда при капитализме* — капитализм чорында хәлдән тайдыра торган эш системасы.

**ПОТО'К** *м.* — 1. шарлама; ташкын; *горный поток* — тау шарламасы; 2. агым, агыш, агылыш; *людской поток* — кешеләр агымы; 3. *спец.* конвейер ысулы; *выработка обуви переведена на поток* — аяк кие-

ме эшләп чыгару конвейер ысулына күчерелгән; 4. поток (нинди дә булса занятиене билгеле бер чират тәртибендә үтә торган укучылар төркеме). ◇ **Отдать на поток и разграбление** *книж.*— акыртып талауга юл кую, оятсыз рәвештә талауга юл кую. **Поток слов** — сүз ташкыны. **Поток слёз** — күз яшьләре дәрьясы. **Поток ругательств** — бертуктаусыз сүгенү, бертуктаусыз әшәке сүзләр әйтү.

**ПОТОЛКА'ТЬ** *сов.*— төрткәләү; *потолкай соседа, чтобы проснулся* — төрткәлә күршеңне, уянсын.

**ПОТОЛКА'ТЬСЯ** *сов. просторен.*— 1. төрткәләү, төрткәләп карау; *потолкались в дверь — не открывают!* — ишекне төрткәләп карадык — ачмыйлар! 2. буталып йөрү; бәрелеп-сугылып йөрү; *потолкаться по городу* — шәһәрдә буталып йөрү.

**ПОТОЛКОВА'ТЬ** *сов. разг.*— бераз сөйләшеп утыру, бераз сөйләшеп алу, гәпләшү, гәпләшеп алу.

**ПОТОЛО'К** *м.*— 1. түшәм; 2. *перен.* күтәрелүнең иң югары ноктасы (самолёт турында әйтелә). ◇ **С потолка** *разг. ирон.*— уйлап-нитеп тормыйча, түшәмнән алып, дәлилсез. **Плевать в потолок** — түшәмгә төкереп яту.

**ПОТОЛО'ЧИНА** *ж. спец.*— түшәм өрлеге.

**ПОТОЛО'ЧНЫЙ** — 1. түшәм...ы; *потолочная балка* — түшәм өрлеге; 2. *перен. разг. шутл. ирон.* түшәмнән алынган, очраклы; *потолочные сведения* — түшәмнән алынган мәгълүматлар.

**ПОТОЛО'ЧЬ** *сов.*— бераз төю; *потолочь крупу* — бераз ярма төю.

**ПОТОЛО'ЧЬСЯ** *сов. просторен.*— буталып йөрү, эшсез йөрү.

**ПОТОЛСТЕ'ТЬ** *сов.*— бераз юанаю, бераз юанаеп китү, бераз калынаю.

**ПОТО'М** *нареч.*— аннан соң, аннары, соныннан.

**ПОТО'МНЫЙ** *м. спец.*— томлап, һәр томга аерым.

**ПОТО'МОК** *м. книж.*— 1. нәсел, токым; 2. *только мн.* (*люди будущих поколений*) киләчәк буыннар, киләчәк буын кешеләре.

**ПОТО'МСТВЕННЫЙ** — 1. *устар.* нәселдән килгән, ата-бабадан килгән; *потомственное имение* — нәселдән килгән имение; 2. *разг.* (*настоящий, исконный*) чын, төп; *потомственный пролетарий* — чын пролетарий.

**ПОТО'МСТВО** *ср. мн.* нет, *собир.*— нәсел, токым, буын, бала-чага; *умер, не оставив потомства* — үлде, бала-чагасы калмады.

**ПОТОМУ'** *нареч.* — шуңа күрә, шул сәбәпле, шунлыктан, шуның өчен; *я заболел, потому не мог прийти* — мин авырдым, шуңа күрә килә алмадым. ◇ **Потому что** *союз* — чөнки; *я не приду, потому что занят* — мин килә алмыйм, чөнки эшем бар.

**ПОТОНУ'ТЬ** *сов.*— бату, батып китү; *потонуть в снегу* — карга бату.

**ПОТОНЧА'ТЬ** *сов.*— бераз юкара төшү, нечкәрә төшү.

**ПОТО'П** *м.*— ташкын, су басу. ◇ **Всемирный потоп** — туфан. **До потопа** *разг. шутл.*— әллә кайчан, бик борын заманда.

**ПОТО'ПАТЬ** *сов. разг.*— 1. тыпырдату, тыпырдатып алу, тыпырдатып кую; *ребёнок потопал ножкой* — бала аякларын тыпырдатып куйды; 2. *шутл. фам. просторен.* китү, тәпи-тәпи китү; *потопали домой* — өйгә кайтып киттеләр.

**ПОТОПА'ТЬ** *несов. просторен. устар.*— к. тонуть.

**ПОТОПИ'ТЬ** I *сов.* — 1. ягып алу; *потопить печь* — мич ягып алу; 2. эретеп алу; *потопить воск* — балавыз эретеп алу.

**ПОТОПИ'ТЬ** II *сов.*— батыру; *потопить неприятельский крейсер* — дошман крейсерын батыру.

**ПОТОПЛЕ'НИЕ** *ср.* — к. потопить II.

**ПОТОПЛЯ'ТЬ** *несов. книж.*— к. потопить II.

**ПОТОПЛЯ'ТЬСЯ** *несов. книж. страд.*— батырылу.

**ПОТО'ПНУТЬ** *сов. просторен. обл.*— к. потонуть.

**ПОТОПТА'ТЬ** *сов.*— таптау, таптап бетерү; *потоптать траву* — үләнне таптап бетерү.

**ПОТО'ПЫВАТЬ** *несов. разг.*— таптанып тору.

**ПОТОРА'ПЛИВАТЬ** *несов. разг.*— ашыктырып тору, ашыктыра төшү, ашыктыру.

**ПОТОРА'ПЛИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— ашыгу, ашыга төшү, тизрәк булу; *ну, поторапливайся, давно пора домой* — я, тизрәк бул, күптән өйгә кайтырга вакыт.

**ПОТОРГОВА'ТЬ** *сов. разг.*— 1. бераз сәүдә итү, бераз сату итеп алу; 2. *устар.* бераз сатулашу, сатулашу, сатулашып карау; *поторговал я ныне дров на рынке, да дброги* (*Даль*) — мин бүген базарда утын сатулашып караган идем дә — кыйммәт.

**ПОТОРГОВА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— сатулашу, сатулашып йөрү.

**ПОТОРГО'ВЫВАТЬ** *несов. разг.*— сату иткәләштерү.

**ПОТОРМОШИ'ТЬ** *сов. разг.*— тарткалау, тарткалап уяту; *потормошить за рукав спящего* — йоклаган кешене җиңеннән тарткалап уяту.

**ПОТОРОПИ'ТЬ** *сов.*— ашыктыра төшү, тизләтү; *поторопить со сдачей экзаменов* — имтихан бирүне тизләтү.

**ПОТОРОПИ'ТЬСЯ** *сов.* — ашыга төшү, тизрәк булу; *поторопитесь, не отставайте* — тизрәк булыгыз, артта калмагыз.

**ПОТОРЧА'ТЬ** *сов. разг. фам.* — бераз басып тору.

**ПОТОЧИ'ТЬ** *сов.* — бераз үткенләү, үткенләп алу, бераз чарлап алу, кайрап алу; *поточить нож* — пычакны үткенләп алу; пычакны кайрап алу.

**ПОТО'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *спец.* — конвейер (методы) белән эшләү; *поточность производства* — производствоның конвейер методы белән эшләве.

**ПОТО'ЧНЫЙ** *спец.* — конвейер системасы белән...; *поточная система производ-*

*ства* — производствоның конвейер системасы белән эшләве.

**ПОТОЩА'ТЬ** *сов. простореч.*— к. отощать.

**ПОТРА'ВА** *ж.*— таптау, таптату (үсеп утырган игенне һ. б.).

**ПОТРАВИ'ТЬ** I *сов.* — 1. таптау, таптап эштән чыгару, хайван кертеп ашату; *свиньи потравили картофель* — дуңгызлар бәрәңгене таптап эштән чыгарганнар; 2. үтереп бетерү, агулап үтереп бетерү; *всех мышей потравили* — барлык тычканнарны үтереп бетергәннәр; 3. бетерү; *потравить пятна на материи* — материядәге тапларны бетерү. ◇ **Потравить ни в чём не повинного человека** — һичбер гаепсез кешене үртәү.

**ПОТРАВИ'ТЬ** II *сов. мор.*— бераз бушата төшү, бераз җибәрә төшү; *потравить канат* — арканны бераз җибәрә төшү.

**ПОТРА'ВНЫЙ** *спец.*: **потравные деньги** — мал таптаган иген өчен түләнә торган акча.

**ПОТРА'ТИТЬ** *сов.*— 1. тотып бетерү, туздырып бетерү; *потратить все деньги* — барлык акчаны тотып бетерү; 2. әрәм итү; *напрасно потратить время* — бер дә юкка вакыт әрәм итү.

**ПОТРА'ТИТЬСЯ** *сов. разг.*— (акча) тоту, расходлану; *потратился на билет* — (акчаны) билетка тоттым.

**ПОТРА'ФИТЬ** *сов. простореч.*— ярый алу, җаен табу, көен табу, көен күрү; *на него не потрафишь* — аның көен таба алмассың, аңа ярый алмассың.

**ПОТРАФЛЯ'ТЬ** *несов. простореч.*— к. потрафить.

**ПОТРЕ'БА** *ж. разг. устар.*— кирәклек; ихтыяж; *на потребу* — кирәклеккә, ихтыяҗга.

**ПОТРЕБИ'ТЕЛЬ** *м.*— потребитель, кулланучы, сатып алучы; *товары для массового потребителя* — массовый кулланучылар өчен булган товарлар.

**ПОТРЕБИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.*— куллану...-ы; *потребительная стоимость* — куллану кыйммәте.

**ПОТРЕБИ'ТЕЛЬСКИЙ** *книж.*— 1. потребительләр...-ы, кулланучылар...-ы; *потребительская масса* — кулланучылар массасы; 2. куллану...-ы; *потребительская продукция* — куллану продукциясе.

**ПОТРЕБИ'ТЬ** *сов. книж.*— к. потреблять.

**ПОТРЕБЛЕ'НИЕ** *ср. книж.*— куллану; *товары широкого потребления* — киң куллану товарлары.

**ПОТРЕБЛЯ'ТЬ** *несов. книж.*— 1. куллану, тоту; *потреблять топливо* — ягулык тоту; 2. (*съедать, есть*) ашау.

**ПОТРЕБЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— кулланылу, тотылу (акча турында).

**ПОТРЕ'БНОСТЬ** *ж.*— кирәкле булу, кирәклелек, ихтыяҗ, таләп, хаҗәт; *принцип коммунизма: от каждого по его способностям, каждому — по его потребностям* — коммунизмның принцибы: һәркемнән — сәләтенчә, һәркемгә — хаҗәтенчә; *испытывать потребность в чём-н.*— берәр нәрсәгә ихтыяҗ, берәр нәрсәнең кирәклеге; *культурные потребности* — культура ихтыяҗлары.

**ПОТРЕ'БНЫЙ** *книж.*— кирәкле, кирәк булган, зарур; *потребное количество* — кирәк булган сан, кирәкле микъдар.

**ПОТРЕ'БОВАТЬ** *сов.*— 1. таләп итү, сорау; *эти работы потребуют большого внимания* — бу эшләр зур игътибарны таләп итәр; 2. чакыру, килүне таләп итү; *его потребовали к начальнику* — аны начальник янына чакырдылар.

**ПОТРЕ'БОВАТЬСЯ** *сов.*— кирәк булу; *ему потребовалась книга* — аңа китап кирәк булды.

**ПОТРЕВО'ЖИТЬ** *сов.*— бераз борчу, бераз тынычсызлау, бераз мәшәкатьләү.

**ПОТРЕВО'ЖИТЬСЯ** *сов.*— 1. тынычсызлану, борчылу, мәшәкатьләнү; 2. мәшәкатьләнеп алу, бераз тынычсызланып алу, бераз борчылу.

**ПОТРЁПАННЫЙ** — 1. кыршылган, таушалып беткән, тузган, ертык; 2. *перен.* йончыган; *потрёпанный вид* — йончыган кыяфәт.

**ПОТРЕПА'ТЬ** *сов.*— 1. җилфердәтү; *ветер потрепал паруса* — җил җилкәннәрне җилфердәтте; 2. тарткалау; *потрепать за волосы* — чәчләрен тарткалау; 3. туздыру, туздырып бетерү, таушалдырып бетерү; таушалдыру; *потрепать пальто* — пальтоны таушалдыру; 4. талку, талкып бетерү; *мы потрепали весь лён* — без җитенне талкып бетердек. ◇ **Потрепать языком** — юкбарны сөйләп ташлау. **Потрепать нервы** — нервларны бераз бозу. **Потрепать чьё-н. имя** — берәүнең яман атын сату, гайбәтен сату. **Потрепать по щеке** — яңагыннан сөю. **Потрепать по спине** — аркасыннан каккалап кую.

**ПОТРЕПА'ТЬСЯ** *сов. простореч.*— таушалып бетү; *платье потрепалось в дороге* — кием юлда таушалып бетте.

**ПОТРЕ'СКАТЬ** *сов. простореч. вульг.* — бүсү, тыгыну.

**ПОТРЕ'СКАТЬСЯ** *сов.*— чатнау, ярылып бетү, яргаланып бетү; *руки потрескались от мороза* — суыктан куллар ярылып беткән.

**ПОТРЕ'СКИВАТЬ** *несов. разг.*— шартлап-шартлап кую; шырт-шырт итү, шыртшырт итеп кую, чатыр-чотыр итү, шартшорт итеп яну; *потрескивают дрова в печи* — мичтә утын шарт-шорт итеп яна.

**ПОТРЕЩА'ТЬ** *сов. разг.*— бераз шатырдау, бераз шатыр-шотыр итү; шатырдап алу, шытырдап алу, бераз шатырдап тору.

**ПОТРО'ГАТЬ** *сов.* — тотып карау, тоткалап карау; капшап карау; *потрогал новое платье* — яңа күлмәкне тотып карады.

**ПОТРОХА'** *мн.* (*ед.* потрох) — эчебавыры, эче (мәсәлән, кошның, балыкның). ◇ **Выпустить потроха** *простореч. перен.*— эчәкләрен ярып чыгару, эчен тишеп агызу. **Со всеми потрохами** *простореч. шутл.*— башы-аягы белән.

**ПОТРОШИ'ТЬ** *несов.*— 1. эчен алу, эчен ярып тазарту; *потрошить рыбу* — балыкның эчен ярып тазарту; 2. *разг. шутл.* бушату; *потрошить карманы* — кесәләрне

бушату, кесәләрне чистарту (урлап). ◇ **Потрошить покойников** *перен. шутл.*— мәетләрне ярып карау.

**ПОТРУДИ'ТЬСЯ** *сов.*— **1.** көч кую, көч салу, көч сарыф итү, эшләү, күп эшләү; *сегодня потрудился немало* — бүген күп кенә эшләдем; **2.** *повел.* **потрудитесь ...**; әле, ...-чы; *потрудитесь подать* — бирегез әле; *потрудитесь передать* — тапшырыгызчы.

**ПОТРУ'СИТЬ** *сов. разг.* — бераз куркып алу, бераз шүрләп алу, куркып тору, бераз шүрләп тору.

**ПОТРУСИ'ТЬ** *сов.*— бераз кабарту, бераз кагу; *потрусить сена* — печәнне бераз кабарту (кагу).

**ПОТРУ'ШИВАТЬ** I *несов. разг.* — куркыштыру, курыккалау.

**ПОТРУ'ШИВАТЬ** II *несов.*— бераз селеккәләү, бераз каккалау.

**ПОТРЯСА'ТЬ** *несов. книж.*— к. потрясти 2, 3, 4.

**ПОТРЯСА'ТЬСЯ** *несов. книж.*— **1.** тетрәү, селкенү; **2.** *страд.* какшатылу, селкетелү.

**ПОТРЯСА'ЮЩИЙ** *книж.*— котчыккыч, коточарлык, куркынычлы, һәлакәтле.

**ПОТРЯСЕ'НИЕ** *ср. книж.*— какшау, бик зур борчылу, бик тирән борчылу; *душевное потрясение* — бик зур рухи борчылу; *нервное потрясение* — нервларның бик нык какшавы. ◇ **Социальное потрясение** — социаль катастрофа (иҗтимагый тормышның асты-өскә килүе).

**ПОТРЯСТИ'** *сов.*— **1.** кагу, селкү; *потрясти мешок* — капчыкны кагу; *потрясти скатерть* — эскәтерне селкү; **2.** янау; *потрясти мечом* — кылыч белән янау; **3.** селкетү, тетрәтү; *потрясти землю* — җирне селкетү; **4.** *перен.* гаҗәпкә калдыру, хәйран калдыру, таңга калдыру; *игра артиста потрясла зрителей* — артистның уйнавы тамашачыларны таңга калдырды.

**ПОТРЯСТИ'СЬ** *сов.*— **1.** бераз калтыранып тору, калтыранып тору, бераз дерелдәп тору, бераз дерелдәү; *потрясся от страха* — куркуыннан бераз калтыранып торды; **2.** *книж.* к. потрясаться 1.

**ПОТРЯ'ХИВАТЬ** *несов. разг.*— селеккәләү, селеккәләп кую; *конь потряхивает гривой* — ат ялын селеккәләп куя.

**ПОТУ'ГИ** *мн.*— **1.** тулгак; *родовые потуги* — тулгак тоту; **2.** *разг. пренебр.* (*бесплодные усилия*) көчәнү, көчәнеп маташу.

**ПОТУЖИ'ТЬ** *сов. разг.*— бераз кайгыру, бераз кайгырып алу; *потужить о сыне* — улы турында бераз кайгыру.

**ПОТУЗИ'ТЬ** *сов. просторец.*— бераз тукмап алу, дөмбәсләү, кыйнау.

**ПОТУ'ПИТЬ** *сов.*— башны түбән ию. ◇ **Потупить взор** — аска карау.

**ПОТУПИ'ТЬ** *сов. разг.*— үтмәсләндерү; *потупить нож* — пычакны үтмәсләндерү.

**ПОТУ'ПИТЬСЯ** *сов.*— башны түбән ию, аска карау.

**ПОТУПЛЯ'ТЬ** *несов.*— к потýпить.

**ПОТУПЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— к. потупиться.

**ПОТУРИ'ТЬ** *сов. просторец.*— куып чыгару; *всех со двора потурили* (*Даль*) — барысын да ишек алдыннан куып чыгардылар.

**ПОТУСКНЕ'ЛЫЙ** — **1.** тоныкланган, төсе киткән, ялтыравыгы беткән; *потускнелое серебро* — тоныкланган көмеш; **2.** сүнгән, дәртсез, рухсыз; *потускнелый взгляд* — сүнгән караш.

**ПОТУСКНЕ'ТЬ** *сов.*— **1.** тону, тоныклану, ялтыравыгы бетү, төсе китү; *медь потускнела* — бакырның ялтыравыгы беткән; **2.** сүнү, рухсызлану, караңгылану, дәртсезләнү; *взор его потускнел* — аның күз карашы дәртсезләнде.

**ПОТУ'СКНУТЬ** *сов. разг.*— к. потускнеть.

**ПОТУСТОРО'ННИЙ** *религ.*— теге дөньядагы, ахирәттәге.

**ПОТУХА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— к. потухать.

**ПОТУХА'ТЬ** *несов.* — к. потухнуть.

**ПОТУ'ХНУТЬ** *сов.*— сүнү; *папироса потухла* — папирос сүнде.

**ПОТУЧНЕ'ТЬ** *сов.*— калынаеп китү, симереп китү.

**ПОТУШЕВА'ТЬ** *сов. разг.*— бераз тушьлау, бераз тушьлап алу, күләгәләндерү (рәсем төшергәндә).

**ПОТУШИ'ТЬ** I *сов.*— сүндерү; *потушить пожар* — янгынны сүндерү.

**ПОТУШИ'ТЬ** II *сов.*— томалап пешерү, үз парында пешерү; *потушить мясо* — итне томалап пешерү.

**ПО'ТЧЕВАТЬ** *несов.*— сыйлау; кыстап-кыстап сыйлау.

**ПОТЩИ'ТЬСЯ** *сов. книж. устар.*— тырышып карау.

**ПОТЫ'КАТЬ** *сов. разг.*— чәнчеп-чәнчеп алу.

**ПОТЫ'ЛИЦА** *ж. обл.*— баш чүмече, баш арты.

**ПО'ТЯГ** *м. спец. обл.*— **1.** үзенә таба тарту; *удар с потягом* — үзенә таба тартып сугу; **2.** (*упряжной ремень в собачьей упряжи*) эт җигә торган каеш; **3.** (*инструмент шерстобита*) кереш, җәя (йон тетү коралы).

**ПОТЯГА'ТЬ** *сов. обл.*— тарту, йолку.

**ПОТЯГА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — **1.** сынашып карау, көч сынап карау; *потягаться в знаниях* — белемнәрне сынашып карау; **2.** судлашып йөрү (берникадәр вакыт).

**ПОТЯ'ГИВАНИЕ** *ср. мн.* нет — к. потягивать, потягиваться.

**ПОТЯ'ГИВАТЬ** *несов.*— **1.** азлап-азлап тарту, акрын-акрын тарту, тартып-тартып кую; *потягивать верёвку* — бауны акрын-акрын тарту; **2.** *разг. фам.* акрынлап эчү; азлап-азлап эчү; *потягивать чай из стакана* — стаканнан акрынлап чәй эчү; **3.** *разг.* акрынлап тәмәке тарту, пыскытып утыру; *потягивать из трубки* — трубка пыскыту.

**ПОТЯ'ГИВАТЬСЯ** *несов.*— киерелү, сузылу.

**ПОТЯГО'ТА** *ж. мн.* нет, *разг.* — к. потягиваться.

**ПОТЯНУ'ТЬ** *сов.*— **1.** тарту; *потянуть за рукав* — җиңеннән тарту; **2.** иртеп алып китү; *товарищ потянул меня в театр* —

иптәшем мине театрга ияртеп алып китте; 3. тарту; *курица потянула два кило* — тавык ике кило тартты; 4. исә башлау; *потянул предрассветный ветерок* — таң алды җиле исә башлады. ◇ **Домой потянуло** — өйгә кайтасы килеп китте. **Потянуло ко сну** — йокы килә башлады.

**ПОТЯНУ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. үрелү, сузылу; сузылып китү, сузыла башлау; *потянуться через стол* — өстәл аркылы үрелү; *за деревней потянулись поля* — авыл артыннан басулар сузылып киткән; 2. башлану; *потянулись долгие зимние вечера* — озын кышкы кичләр башланды; 3. артыннан китү, ияреп китү, ияреп китеп бару; *за ним потянулись на юг друзья* — аның артыннан көньякка дуслары да китте; 4. киерелеп кую, сузылып кую; *он потянулся и глубоко вздохнул* — ул киерелеп куйды да тирән сулыш алды.

**ПОУБА'ВИТЬ** *сов. разг.* — бераз киметү, бераз кыскарту, бераз кимәтә төшү.

**ПОУГОМОНИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — бераз тыну, тына төшү; *дети к вечеру поугомонились* — балалар кичкә таба бераз тындылар.

**ПОУДИ'ТЬ** *сов.* — балык тотып алу, балык тоту; *утром два часа поудил* — иртән ике сәгать балык тоттым.

**ПОУ'ЖИНАТЬ** *сов.* — кичке аш ашап алу.

**ПОУЛЕ'ЧЬСЯ** *сов. разг.* — 1. ятып бетү; *все поулеглись спать* — барысы да йокларга ятып бетте; 2. *перен.* басылу, тынычлану; *гнев его поулёгся* — аның ачуы басылды.

**ПОУМНЕ'ТЬ** *сов.* — акыллылану, акыллылана төшү.

**ПОУ'МНИЧАТЬ** *сов. разг.* — бераз акыл сату.

**ПОУ'МСТВОВАТЬ** *сов. разг.* — фәлсәфә сату, фәлсәфә сатып маташу.

**ПОУПО'РСТВОВАТЬ** *сов.* — үз сүзендә торырга тырышу; бераз үзенекен итәргә тырышу; бераз каршылык күрсәтү.

**ПОУПРА'ВИТЬСЯ** *сов. просторен.* — эшне бетерү, котылу, бушау, бушану; *поуправиться с детьми* — балалар белән эшне бетерү, балалардан бушау.

**ПОУПРЯ'МИТЬСЯ** *сов.* — бераз киреләнү, бераз тискәреләнү, бераз үзсүзлеләнү; *сперва поупрямился, но потом согласился ехать* — башта бераз киреләнде дә, соңыннан барырга риза булды.

**ПОУРО'ЧНЫЙ** — дәресләп, дәрес башыннан; *поурочная оплата* — дәрес башыннан түләү.

**ПОУСЕ'РДСТВОВАТЬ** *сов. разг.* — бераз тырышлык күрсәтеп алу, тырышлык күрсәтү.

**ПОУСПОКО'ИТЬСЯ** *сов. разг.* — бераз тынычлану, бераз тынычлана төшү; *он теперь поуспокоился* — ул хәзер бераз тынычланды.

**ПОУСТАРЕ'ТЬ** *сов. разг.* — бераз искерү, искерә төшү.

**ПОУТРУ'** *нареч. разг.* — иртә белән, иртән, иртүк.

**ПОУТЮ'ЖИТЬ** *сов.* — үтүкләү, үтүкләп алу; *поутюжить брюки* — чалбарны үтүкләп алу.

**ПОУЧА'ТЬ** *несов.* — 1. *книж. ритор. устар.* (*учить*) өйрәтү, укыту; 2. *разг. ирон.* (*говорить наставительным тоном*) үгетләү, вәгазьләү, акыл өйрәтү.

**ПОУЧА'ТЬСЯ** *несов. книж. ритор. устар. и разг. ирон.* — өйрәнү, сабак алу.

**ПОУЧЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *книж. и разг. ирон.* (*назидательный совет*) үгет-нәсихәт; 2. (*проповедь*) вәгазь.

**ПОУ'ЧИВАТЬ** *несов. разг. фам.* — акрынлап өйрәтү, аз-маз өйрәткәләштерү, өйрәткәләү.

**ПОУЧИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — гыйбрәтлелек, гыйбрәтле булу.

**ПОУЧИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — 1. өйрәтә торган, үгетли торган, вәгазьли торган; *поучительный совет* — үгетли торган киңәш; 2. сабак булырлык; гыйбрәтле, үрнәк булырлык; *поучительная история* — сабак булырлык вакыйга.

**ПОУЧИ'ТЬ** *сов.* — 1. бераз уку, бераз ятлау; *поучить урок* — бераз дәрес уку (хәзерләү); *поучить стихотворение* — бераз шигырь ятлау; 2. бераз өйрәтү; *поучить сапожному делу* — бераз итек тегү һөнәренә өйрәтү; 3. *простореч. фам.* кыйнау, тукмау, өйрәтү, арт сабагын укыту.

**ПОУЧИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. бераз өйрәнү; *поучиться переплетать книги* — китап төпләргә бераз өйрәнү; 2. *разг.* бераз дәрес хәзерләп алу; *немного поучусь, а потом поиграю* — бераз дәрес хәзерләп алыйм да аннары уйнармын.

**ПОФАНТАЗИ'РОВАТЬ** *сов.* — бераз хыяллану, бераз уйланып алу, бераз хыялланып алу, хыялларга бирелеп китү.

**ПОФАРТИ'ТЬ** *сов. безл. простореч.* — мач килү, җай килү.

**ПОФИЛОСО'ФСТВОВАТЬ** *сов.* — бераз фәлсәфәгә бирелү, фәлсәфә сатып алу.

**ПОФОРСИ'ТЬ** *сов. простореч. фам.* — бераз көязләнеп йөрү, форсить итеп алу.

**ПОФРАНТИ'ТЬ** *сов.* — купшыланып алу, көязләнеп алу.

**ПОФЫ'РКАТЬ** *сов. разг.* — 1. (*издать несколько фыркающих звуков*) пошкырып-пошкырып кую; 2. *перен. фам.* (*поворчать*) сукранып алу, мыгырданып кую.

**ПОФЫ'РКИВАТЬ** *несов. разг.* — пошкырып-пошкырып кую, пошкырып кую; *кони пофыркивали* — атлар пошкырып-пошкырып куялар иде.

**ПОХА'БИТЬ** *несов. простореч. вульг.* — кабахәтләндерү, бозу, пычрату.

**ПОХА'БНИК** *м.*, **ПОХА'БНИЦА** *ж. простореч. вульг.* — оятсыз, әдәпсез кеше, пычрак телле кеше.

**ПОХА'БНИЧАТЬ** *несов. простореч. вульг.* — оятсыз, әдәпсез сүзләр сөйләү, әшәкелек эшләү, бозыклык эшләү.

**ПОХА'БНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *простореч. вульг.* — бозыклык, әшәкелек, пычрак теллелек, оятсызлык.

**ПОХА'БНЫЙ** — 1. *простореч. вульг.* оятсыз, әдәпсез; *похабное ругательство* — оятсыз сүгенү; 2. (*позорный*) хурлыклы.

**ПОХА'БСТВО** *ср. мн.* нет, **ПОХА'БЩИ-**

НА *ж. мн.* нет, *простореч. вульг.*— әшәке сүзләр, оятсыз тиргәшүләр, оятсыз кыланышлар, кабахәт кыланышлар.

**ПОХА'ЖИВАТЬ** *несов. разг.*— **1.** арлы-бирле йөрү; *похаживать по комнате* — бүлмәдә арлы-бирле йөрү; 2. килгәләү, баргалау; *он к нам частенько похаживает* — ул безгә еш кына килгәли.

**ПОХАНДРИ'ТЬ** *сов.*— бераз пошыну, бераз күңел төшеп тору, бераз төшенкелеккә бирелеп йөрү, бераз кәефсезләнү.

**ПОХА'ЯТЬ** *сов. простореч.* - яманлау, яманлап алу.

**ПОХВАЛА'** *ж.*— мактау, хуплау.

**ПОХВА'ЛИВАТЬ** *несов. разг.*— мактап тору, вакыт-вакыт мактау.

**ПОХВАЛИ'ТЬ** *сов.*— мактау, мактап алу, мактап куюю.

**ПОХВАЛИ'ТЬСЯ** *сов.*— мактанып алу, мактану, шапырыну.

**ПОХВАЛЬБА'** *ж. разг.*— мактанчыклык, шапырынучанлык.

**ПОХВА'ЛЬНЫЙ** *книж.*— **1.** мактауга лаек; *похвальное усердие* — мактауга лаек тырышлык; 2. мактау...-ы; *похвальный лист* — мактау кәгазе.

**ПОХВАЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. похвалить.

**ПОХВАЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— к. похвалиться.

**ПОХВА'РЫВАТЬ** *несов. разг.*— чирләштергәләү, авырып тору, авыргалаштыру.

**ПОХВА'СТАТЬ** *сов.*— мактану, мактанып алу, шапырынып алу.

**ПОХВА'СТАТЬСЯ** *сов.*— мактанып алу, шапырынып алу.

**ПОХВАТА'ТЬ** *сов. разг.*— **1.** тоткалау; 2. капкалау; *окунь похватал червяка, да и ушёл* — алабуга суалчанны капкалады да китте; 3. эләктереп алу; *дети похватали конфеты и убежали* — балалар конфетларны эләктереп алдылар да, йөгереп киттеләр; 4. *простореч.* бер-бер артлы кулга алу; *хулиганов всех похватали* — хулиганнарның барысын да бер-бер артлы кулга алдылар.

**ПОХВОРА'ТЬ** *сов.*— чирләп алу, авырып алу.

**ПОХЕ'РИТЬ** *сов. разг. фам.*— сызып ташлау, юкка чыгару, бетерү.

**ПОХИТИ'ТЕЛЬ** *м. книж.*— урлаучы, урлап алып китүче.

**ПОХИ'ТИТЬ** *сов.*— урлап алып китү, урлау, чәлдерү.

**ПОХИТРИ'ТЬ** *сов.*— хәйләләү, бераз хәйләләү.

**ПОХИХИ'КАТЬ** *сов.*— хихылдап көлеп алу, хихылдап көлү.

**ПОХИЩА'ТЬ** *несов. книж.*— к. похитить.

**ПОХИЩА'ТЬСЯ** *несов. книж. страд.*— урлап алып кителү, урлану.

**ПОХИЩЕ'НИЕ** *ср. книж.*— к. похитить, похищать.

**ПОХЛЕБА'ТЬ** *сов. простореч.*— ашап алу (кашык белән сыек ашны).

**ПОХЛЁБКА** *ж.* — шулпа, сыек аш. ◇ **Продать за чечевичную похлёбку** — бер тиен акча өчен сатып җибәрү, бер тиен акча өчен хыянәт итү, бер тиенгә сату.

**ПОХЛЁБЫВАТЬ** *несов. простореч.* — ашыкмыйча гына ашау (кашык белән сыек ашны).

**ПОХЛЕСТА'ТЬ** *сов. разг.*— **1.** (камчы, чыбык белән) бераз сыдыру, сыдырып алу; 2. суккалау, чабу; *похлестать спину веником* — арканы мунча себеркесе белән чабу.

**ПОХЛЁСТЫВАТЬ** *несов. разг.* — суккалау, сыдыргалау.

**ПОХЛО'ПАТЬ** *сов.*— чабаклау, суккалау; *похлопать по плечу* — җилкәгә суккалау. ◇ **Похлопать в ладоши** — кул чәбәкләү.

**ПОХЛОПОТА'ТЬ** *сов.*— **1.** юллау, кайгырту, артыннан йөрү; *похлопотать о приятеле* — иптәш турында кайгырту; 2. мәшәкатьләнү, мәшәкатьләнеп йөрү; *похлопотала по хозяйству и устала* — хуҗалык эшләре белән мәшәкатьләнеп йөреп арыдым.

**ПОХМЕЛЕ'ТЬ** *сов. разг.*— исереп китү.

**ПОХМЕЛИ'ТЬСЯ** *сов. простореч. обл.*— баш төзәтү.

**ПОХМЕ'ЛЬЕ** *ср. мн.* нет — похмил, макмыр. ◇ **В чужом пиру похмелье** — ак эт баласе кара эткә, кеше эчкәнгә баш төзәтү.

**ПОХМЕЛЯ'ТЬСЯ** *несов. простореч. обл.*— к. похмелиться.

**ПОХМЫ'КАТЬ** *сов. простореч.* — һем-һем итеп алу.

**ПОХМЫ'КИВАТЬ** *несов. простореч.* — һем-һем итеп тору.

**ПОХНЫ'КАТЬ** *сов. разг.*— бераз шыңшып алу.

**ПОХО'Д** *м.*— **1.** поход (а. гаскәрләрнең берәр төрле бурычны үтәү өчен бер урыннан икенче урынга күчүе; б. берәүгә каршы алып барылган сугыш хәрәкәтләре; в. *перен.* оешкан рәвештә каршы чыгу); 2. *разг.* пахут, артык; *три килограмма с походом* — артыгы белән өч килограмм. ◇ **За (одним) походом** *разг. фам.*— юл уңаенда, бер уңайдан.

**ПОХОДА'ТАЙСТВОВАТЬ** *сов.*— юллау, артыннан йөрү (берәр эшнең).

**ПОХОДИ'ТЬ** I *сов.*— бераз йөреп алу, бераз йөрү, йөренү; *походил по базару* — бераз базарда йөрдем.

**ПОХОДИ'ТЬ** II *несов.*— охшау, охшаш булу; *нравом он походил на отца* — холкы белән ул атасына охшаган иде.

**ПОХО'ДКА** *ж.*— йөреш; *степенная походка* — салмак йөреш.

**ПОХО'ДНЫЙ** — **1.** поход...-ы; *походная кухня* — поход кухнясы; 2. күчмә; *походный лазарет* — күчмә лазарет.

**ПО'ХОДЯ** *нареч. разг.*— **1.** барганда, йөргәндә; *нельзя походя есть* — йөргәндә ашарга ярамый; 2. (*заодно, мимоходом*) бер уңайдан, беррәттән.

**ПОХОЖДЕ'НИЕ** *ср.*— баштан үткәннәр, күргәннәр, булган вакыйгалар, маҗаралар.

**ПОХО'ЖИЙ** — охшашлы, охшаган, охшаш. ◇ **Ни на что не похоже** — бик начар. **Похоже на то, что** *разг.* — ... сыман; *похоже на то, что будет дождь* — яңгыр булырсыман. **Похож, как две капли воды** — койган да куйган, суйган да каплаган. **Это на тебя не похоже** — бу синнән

һич көтелмәгән иде, моны син эшләрсең дип уйламаган идек.

**ПОХОЗЯ'ЙНИЧАТЬ** *сов.*— бераз хуҗа булып алу, бераз хуҗалык эшләре белән шөгыльләнү.

**ПОХОЗЯ'ЙСТВОВАТЬ** *сов. разг.*— к. похозяйничать.

**ПОХОЛОДА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *спец.*— салкынаю, суыту.

**ПОХОЛОДА'ТЬ** *сов.*— 1. (*стать холоднее*) суыта төшү, салкыная төшү; 2. *обл.* суыну; *руки уже похолодали* — куллары суынган инде; 3. *разг.* (*иззябнуть*) туңып бетү, өшеп бетү.

**ПОХОЛОДЕ'ТЬ** *сов.*— салкын йөгерү, суынып китү, салкынаю, салкынаеп китү; *от испуга похолодели руки и ноги* — куркуымнан аяк-кулларыма салкын йөгерде.

**ПОХОРОНИ'ТЬ** *сов.*— 1. күмү, җирләү (мәетне); 2. *перен. разг.* оныту; *похоронить воспоминания* — истәлекләрне оныту.

**ПОХОРО'ННЫЙ** — 1. күмү...-ы; мәет озату ...-ы; *похоронная процессия* — мәет озату процессиясе; 2. *разг.* (*печальный, скучный*) кайгылы, хәсрәтле. ◇ **Похоронный марш** — матәм маршы.

**ПО'ХОРОНЫ** *ед.* нет — мәетне күмү, җирләү; *торжественные похороны* — тантаналы күмү.

**ПОХОРОШЕ'ТЬ** *сов.*— матурланып китү, чибәрләнеп китү, яхшыра төшү.

**ПОХОТЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — җенси теләккә бирелү, җенси дәрткә бирелүчәнлек.

**ПОХОТЛИ'ВЫЙ** — хайвани теләкле, җенси теләкле, җенси дәрткә бирелүчән; *похотливый взгляд* — җенси теләкле караш.

**ПО'ХОТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— хайвани теләк, җенси теләк, җенси дәрт.

**ПОХОХА'ТЫВАТЬ** *несов. разг.*— вакытвакыт шаркылдап көлү, шаркылдап көлгәләү.

**ПОХОХОТА'ТЬ** *сов.*— бераз көлеп алу, шаркылдап көлеп алу.

**ПОХРАБРЕ'ТЬ** *сов. разг.*— кыюланып китү, батырланып китү, кыюрак булып китү.

**ПОХРАБРИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — бераз кыюлык күрсәтергә маташу, бераз гайрәт чәчеп алу, бераз гайрәтләнеп алу.

**ПОХРА'МЫВАТЬ** *несов. разг.* — азрак аксау, аксаштыргалау; *лошадь начала похрамывать* — ат азрак аксый башлады.

**ПОХРАПЕ'ТЬ** *сов.* — бераз гырылдап алу, гырылдау.

**ПОХРА'ПЫВАТЬ** *несов. разг.* — акрын гына гырылдау, сирәк-мирәк гырылдау.

**ПОХРОМА'ТЬ** *сов.*— бераз аксаклап йөрү, бераз чатанлап йөрү.

**ПОХУДА'ТЬ** *сов. обл.*— к. похудеть.

**ПОХУДЕ'ЛЫЙ** — ябык, ябыккан, арык; *похуделый ребёнок* — ябык бала.

**ПОХУДЕ'ТЬ** *сов.*— ябыгу, ябыга төшү, арыгаю, арыклану.

**ПОХУЖЕ'ТЬ** *сов. обл.*— начарлану, начарланып китү.

**ПОХУ'Л** *м.*, **ПОХУ'ЛКА** *ж. простореч.*— к. охулка.

**ПОХУЛИ'ТЬ** *сов. устар.* и *простореч.*— яманлап алу, тиргәп алу.

**ПОЦАРА'ПАТЬ** *сов.*— тырнау, тырнап алу.

**ПОЦАРА'ПАТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. тырналып бетү; *поцарапаться о проволоку* — тимер чыбыкка тырналып бетү; 2. бераз сыдырылу, сыдырылып бетү; *шкаф при перевозке поцарапался* — күчергәндә шкаф бераз сыдырылган; 3. *перен. шутл.* сугышып алу, ызгышып алу.

**ПОЦЕДИ'ТЬ** *сов.*— бераз саркытып алу, бераз сөзеп алу, бераз агызып алу.

**ПОЦЕ'ЖИВАТЬ** *несов. разг.*— вакытвакыт сөзү, азлап-азлап саркыту, саркытып алгалау.

**ПОЦЕЛОВА'ТЬ** *сов.* — үбү, үбеп алу. ◇ **Поцеловать замок или пробой** *простореч. шутл.*— өйдә туры китермәү (ишек бикле булу).

**ПОЦЕЛОВА'ТЬСЯ** *сов.*— үбешү, үбешеп алу.

**ПОЦЕЛУ'Й** *м.*— үбү. ◇ **Поцелуй Иуды** *перен.* — Иуда үбүе (хыянәт итү).

**ПОЦЕРЕМО'НИТЬСЯ** *несов. разг.*— бераз назланып алу, бераз назланып маташу, бераз кыстатып алу, бераз тәкәллефләнеп алу.

**ПОЧА'ВКАТЬ** *сов. разг. фам.*— иреннәрне чапылдатып алу, авыз чапылдатып кую.

**ПОЧАЕВА'ТЬ** *сов. обл. разг. фам.*— к. почаёвничать.

**ПОЧАЁВНИЧАТЬ** *сов. разг. фам.*— чәй эчеп алу.

**ПОЧА'ЙНИЧАТЬ** *сов. обл. разг. фам.*— к. почаёвничать.

**ПОЧА'СНЫЙ, ПОЧАСОВО'Й** — сәгатьләп, сәгать башыннан, сәгать исәбеннән; *почасная оплата* — сәгать исәбеннән түләү.

**ПОЧА'СТУ** *нареч. обл.*— еш; *он почасту у нас бывает* — ул бездә еш булгалый.

**ПОЧАТО'Й** — к. початый.

**ПОЧА'ТОК** *м. спец.*— чәкән; *початок кукурузы* — кукуруз чәкәне.

**ПО'ЧА'ТЫЙ** *устар. обл.*— башлаган; *початая бутылка шампанского* — башлаган шампанский бутылкасы.

**ПОЧА'ТЬ** *сов. устар. обл.*— башлау; төшү; *вчера почали косить* — кичә чаба башладык.

**ПОЧА'ТЬСЯ** *сов. устар. обл.*— башлану.

**ПОЧА'ХНУТЬ** *сов. разг.*— сулу, шиңү; *цветы почахли* — чәчәкләр сулган.

**ПО'ЧВА** *ж. спец.*— 1. туфрак, җир; *чернозёмная почва* — кара туфрак; 2. төп, нигез, таяныч; җирлек; *у него есть почва под ногами* — аның таянычы бар; *выбить почву из-под ног* — таянычтан мәхрүм итү. ◇ **Оставаться на почве фактов** — фактларга таянып эш итү. **На почве чего...** - дан, сәбәпле; *оглох на почве гриппа* — гриптан чукракланган. **На личной почве** — шәхси сәбәпләр аркасында. **Подготовить**

почву для чего-н.— берәр нәрсә өчен шартлар булдыру, җирлек хәзерләү. **Оторваться от своей почвы** — үзенең җирлегеннән аерылу (социаль средадан аерылу).

**ПОЧВА'НИТЬСЯ** *сов. разг.* — һаваланып алу, борын күтәреп йөреп алу.

**ПО'ЧВЕННЫЙ** *тех. с.-х.*— 1. туфрак...-ы, туфраклар...-ы; *почвенная карта* — туфраклар картасы; 2. *перен.* социаль средага бәйләнгән; *человек он был почвенный* — ул социаль средага бәйләнгән кеше иде. ◇ **Почвенные воды** — җир асты сулары.

**ПОЧВОВЕ'Д** *м.*— туфрак белгече, туфрак гыйлеме белгече.

**ПОЧВОВЕ'ДЕНИЕ** *ср. мн.* нет — туфрак белеме, туфрак фәне, туфрак гыйлеме.

**ПОЧВОВЕ'ДЧЕСКИЙ** — 1. туфрак белеме...-ы; *почвоведческая лаборатория* — туфрак белеме лабораториясе; 2. туфрак гыйлеме белгечләре ...-ы; *почвоведческий съезд* — туфрак гыйлеме белгечләре съезды.

**ПОЧВОЗАЩИ'ТНЫЙ** *с.-х.* — туфракны саклау...-ы; *почвозащитная роль лесов* — урманнарның туфракны саклау роле.

**ПОЧВООБРАБА'ТЫВАЮЩИЙ** *тех. с.-х.*— туфрак эшкәртү...-ы, туфрак эшкәртә торган; *почвообрабатывающие машины* — туфракны эшкәртә торган машиналар.

**ПОЧВОУГЛУБИ'ТЕЛЬ** *м. с.-х.*— туфрак тирәнәйткеч (махсус сабан).

**ПОЧВОУГЛУБИ'ТЕЛЬНЫЙ** *с.-х.*— туфрак тирәнәйтү ...-ы; *почвоуглубительные работы* — туфрак тирәнәйтү эшләре.

**ПОЧВОУТОМЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *с.-х.*— туфрак алҗуы (бер төрле игенне бер урынга күп еллар буе чәчүдән туфракның ул игенне уңдырмый башлавы).

**ПОЧЕЛО'МКАТЬСЯ** *сов. простореч. фам.*— 1. *обл. (поздороваться)* исәнләшү, сәлам бирү, баш иеп исәнләшү; 2. *(поцеловаться)* үбешү.

**ПОЧЁМ** *нареч.*— 1. ни хак, ни бәя, күпме тора; *почём мука* — он ни хак? ◇ **Почём я знаю?** — мин каян белим? **Почём знать?** — кем белсен?

**ПОЧЕМУ'** *нареч.*— ни өчен, нигә, ни сәбәпле; *почему ты так думаешь?*—ни өчен син алай дип уйлыйсың?

**ПОЧЕМУ'-ЛИБО, ПОЧЕМУ'-НИБУДЬ** *нареч.*— нинди дә булса бер сәбәп белән, ниндидер бер сәбәп аркасында.

**ПОЧЕМУ'-ТО** *нареч.*— ни өчендер, ни сәбәптәндер, нилектәндер; *почему-то не приехал во-время* — ни өчендер вакытында килмәгән.

**ПО'ЧЕРК** *м.*— почерк, язу рәвеше, язу; *у него хороший почерк* — аның язуы матур.

**ПОЧЁРКАТЬ** *сов. разг.*— сызгалап бетерү; *редактор почёркал статью* — редактор мәкаләне сызгалап бетергән.

**ПОЧЕРНЕ'ЛЫЙ** — каралган, кара төскә кергән; *почернелые пни* — каралган агач төпләре.

**ПОЧЕРНЕ'ТЬ** *сов.*— каралу; *стены почернели от копоти* — стеналар сөремнән каралган.

**ПОЧЕРНИ'ТЬ** *сов.*— бераз каралту; *почернить линейку* — линейканы бераз каралту.

**ПОЧЕ'РПАТЬ** *сов.*— чумырып алу.

**ПОЧЕРПА'ТЬ** *несов. книж.*— к. почерпнуть 2.

**ПОЧЕРПНУ'ТЬ** *сов.*— 1. *(зачерпнуть немного)* бераз чумырып алу; 2. *перен.* алу, файдалану; *почерпнуть сведения из книг* — китаплардан мәгълүматлар алу.

**ПОЧЕРСТВЕ'ТЬ** *сов.*— бераз кату, бераз искерү; *хлеб почерствел* — икмәк бераз искергән, икмәк бераз каткан.

**ПОЧЕРТИ'ТЬ** *сов. разг.*— сызып алу, бераз сызып алу, бераз сызу, чертёж ясап алу.

**ПОЧЕСА'ТЬ** *сов.*— 1. бераз кашып алу; *почесать спину* — арканы бераз кашып алу; 2. тарап алу, бераз тарап алу; *почесать волосы* — чәчне бераз тарап алу; 3. *простореч. (идти, бежать)* табан ялтырату, элдертү. ◇ **Почесать языком** — бераз ләчтит сату.

**ПОЧЕСА'ТЬСЯ** *сов.*— 1. бераз кашынып алу, кашынып алу; *собака почесалась* — эт кашынып алды; 2. *безл.* бераз кычыту; *почесалось и перестало*—бераз кычытты да бетте. ◇ **Он и не почешется** — ул кыл да кыймылдатмас, аның исе дә китмәс.

**ПО'ЧЕСТЬ** *ж. книж.*— хөрмәт, ихтирам, кадер.

**ПОЧЕ'СТЬ** I *сов.*— (... дип) тану, (... дип) белү, (... дип) табу, (... дип) санау; *почту своим долгом* — үземнең бурычым дип белермен; *не почёл нужным идти* — баруны кирәкле дип тапмады.

**ПОЧЕ'СТЬ** II *нареч.*— диярлек; *почесть никого не осталось* — беркем дә калмады диярлек.

**ПОЧЕСУ'ХА** *ж. мед.*— корчаңгы.

**ПОЧЁСЫВАТЬ** *несов. разг.*— кашып-кашып кую, кашыштыру; *почёсывать руки* — кулларны кашыштыру.

**ПОЧЁСЫВАТЬСЯ** *несов. разг.*— 1. кашыну; 2. *фам.* баш кашып тору (аптыраганда).

**ПОЧЁТ** *м.*— хөрмәт, ихтирам, почёт.

**ПОЧЁТНОСТЬ** *ж. книж.*— хөрмәтлелек.

**ПОЧЁТНЫЙ** *книж.*— 1. хөрмәтле, кадерле; *почётный гость* — хөрмәтле кунак; 2. почётлы; *почётный президиум* — почётлы президиум; 3. почёт...-ы; *почётный караул* — почёт каравылы; 4. мактаулы; *почётная работа* — мактаулы эш.

**ПО'ЧЕЧНЫЙ** I *бот. биол.*— бөре ...-ы; *почечная чешуя* — бөре кабыгы.

**ПО'ЧЕЧНЫЙ** II *анат. мед.*— бөер ...-ы; бөердәге; *почечная лоханка* — бөер лаканчыгы; *почечные камни* — бөердәге ташлар.

**ПОЧЕЧУ'Й** *м. мед. устар.*— геморрой авыруы.

**ПОЧИВА'ЛЬНЯ** *ж. устар.*— к. опочивальня.

**ПОЧИВА'ТЬ** *несов.* — 1. *разг. устар.* йоклау; 2. *перен. книж. ритор.* (*по-*

*коиться, быть погребенным*), күмелү, кабердә яту.

**ПОЧИ'ВШИЙ** *книж. ритор. устар.*— үлгән, мәрхүм.

**ПОЧИ'Н** *м. мн.* нет — 1. башлау, башлап җибәрү, почин; 2. инициатива; *смелый почин* — кыю инициатива; *взять на себя почин* — инициативаны үз өстенә алу.

**ПОЧИНА'ТЬ** *несов. устар. обл.*— к. почать.

**ПОЧИНИ'ТЬ** *сов.*— 1. төзәтү, ямау, ипләү; *починить часы* — сәгатьне төзәтү; 2. *разг. фам. шутл.* (*повредить*) имгәтү, бәрү, вату.

**ПОЧИНИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— бераз киреләнеп тору, бераз үз сүзләнеп тору.

**ПОЧИ'НКА** *ж. мн.* нет — к. починить 1.

**ПОЧИ'ННЫЙ** *обл. простореч.* — беренче, башлангыч; *починная дичь на охоте* — ауда беренче атып алынган җәнлек.

**ПОЧИ'НОК** *м. обл.*— пүчинкә (1. *с.-х.* урман эчендә сөрү өчен төпләнгән җир участогы; 2. авылдан аерылып чыккан кечкенә авыл).

**ПОЧИ'НОЧНЫЙ** *спец.* —ямау ...-ы, төзәтү ...-ы; *починочная мастерская* — төзәтү мастерское.

**ПОЧИ'НЩИК** *м. спец.*— төзәтүче, ямаучы.

**ПОЧИНЯ'ТЬ** *несов.*— к. починить.

**ПОЧИНЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— ямалу, төзәтелү.

**ПОЧИРИ'КАТЬ** *сов. разг.*— чер-чер килү, бераз чыркылдап тору, берничә тапкыр чыркылдап кую; *воробей почирикал и вспорхнул* — чыпчык чер-чер килде дә очып китте.

**ПОЧИ'СТИТЬ** *сов.*— 1. тазарту, тазартып алу, чистартып алу; *почистить пальто* — пальтоны чистартып алу; 2 әрчеп алу; *почистить картошку* — бәрәнге әрчеп алу; 3. *перен. простореч.* (*обобрать, обчистить*) урлау, урлап бетерү.

**ПОЧИ'СТИТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. тазартылу, чистартылу; 2. *простореч.* чистару; *пиджак почистился* — пиджак чистарган.

**ПОЧИТА'Й** *нареч. простореч. обл.*— 1. к. почти; 2. мөгаен.

**ПОЧИТА'НИЕ** *ср. мн.* нет — к. почитать II.

**ПОЧИТА'ТЕЛЬ** *м. книж.*— олылаучы, хөрмәтләүче; *я почитатель вашего таланта* — мин сезнең талантыгызны хөрмәтләүче кеше.

**ПОЧИТА'ТЬ** I *сов.*— 1. укып алу, бераз укып алу; *почитать стихи Пушкина* — Пушкин шигырьләрен бераз укып алу; 2. укып карау; *советую почитать эту книгу* — бу китапны укып карарга киңәш бирәм.

**ПОЧИТА'ТЬ** II *несов.*— олылау, хөрмәт күрсәтү, ихтирам итү.

**ПОЧИТА'ТЬ** III *несов. книж. устар.*— (...дип) уйлау, (... дип) тану, (... дип) исәпләү; *почитать героем* — герой дип тану; *почитать своим учителем* — үзенең остазын дип тану.

**ПОЧИТА'ТЬСЯ** I *несов. страд. книж. устар.*— хөрмәт күрсәтелү, ихтирам ителү.

**ПОЧИТА'ТЬСЯ** II *несов. книж. устар.*— (... дип) исәпләнү, (...дип) танылу, (... дип) беленү, (... дип) саналу; *он почитается хорошим писателем* — ул яхшы язучылардан санала.

**ПОЧИ'ТЫВАТЬ** *несов. разг.*— укыштыргалау, вакыт-вакыт укып алу.

**ПОЧИ'ТЬ** *сов. книж. ритор, устар.*— 1. тынычлыкка бирелү, тынычлану; *почить от дел* — эшләрне ташлап тынычлыкка бирелү; 2. (*прекратиться, стихнуть*) тыну, тынып калу; 3. йокыга киту; *почить тихим сном* — тыныч йокыга китте; 4. (*умереть*) үлү, вафат булу. ◇ Почить на лаврах — к. лавр.

**ПОЧИХА'ТЬ** *сов.*— берничә тапкыр төчкерү.

**ПОЧИ'ЩЕ** *нареч. разг.*— 1. тазарак, чистарак, арурак; *выбери бумагу почище* — чистарак кәгазь сайлап ал; 2. *фам.* яхшырак; *почище тебя сделаю* — синнән яхшырак эшләрмен; 3. *фам.* артыграк, ныграк, катырак; *он выразился ещё почище прежнего* — ул элеккедән дә катырак әйтте; 4. (*важнее, знатнее*) затлырак, яхшырак.

**ПО'ЧКА** I *ж. биол.*— 1. бөре; *почки на деревьях* — агачлардагы бөреләр; 2. (*у некоторых низших животных небольшой вырост*) бөерәк.

**ПО'ЧКА** II *ж.*— бөер; *болезни почек* — бөер авырулары.

**ПОЧКОВА'НИЕ** *ср. биол. мн.* нет — 1. женессез үрчү; 2. *разг. шутл.* (*размножаться*) бик тиз үрчү.

**ПОЧКОВА'ТЬСЯ** *несов. биол.*— 1. (*размножаться почкованием*) женессез үрчү; (түбән төзелешле тереклек иярәренә карата әйтелә); 2. *перен. разг. шутл.* (*размножаться во множестве*) бик күп булып үрчү.

**ПОЧКОВИ'ДНЫЙ** *спец.*— бөресыман, бөре рәвешендә булган, бөрегә охшаган.

**ПОЧКОЕ'Д** *м. зоол.*— бөре ашаучы, бөре корты.

**ПОЧМО'КАТЬ** *сов. разг.*— (бераз иреннәрне) чапылдатып алу.

**ПОЧМО'КИВАТЬ** *несов. разг.*— вакыт-вакыт чапылдату, чапылдатып алгалау; *почмокивать губами* — иреннәрне чапылдатып алгалау.

**ПО'ЧТА** *ж.*— почта. ◇ **Разносить почту** *шутл. устар.*— гайбәт сөйләп йөрү.

**ПОЧТАЛЬО'Н** *м.*— почтальон, почта ташучы, хат ташучы.

**ПОЧТА'МТ** *м.*— почтамт (шәһәр почтасының үзәк бүлеге, үзәк идарәсе).

**ПОЧТА'РЬ** *м. простореч* — к. почтальон.

**ПОЧТ-ДИРЕ'КТОР** *м. офиц. истор.*— почтамт директоры.

**ПОЧТЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— хөрмәт, ихтирам; *оказывать почтение* — хөрмәт күрсәтү. ◇ **Моё почтение** *разг. фам.* — сәлам сезгә, сәлам бирдек.

**ПОЧТЕ'ННЕЙШИЙ** — иң хөрмәтле, иң кадерле, бик хөрмәтле, бик кадерле.

**ПОЧТЕ'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— хөрмәтлелек, олылауга лаеклылык. ◇ **Почтенность возраста** — олы яшьтә булу.

**ПОЧТЕ'ННЫЙ** — 1. хөрмәтле, кадерле, олылауга лаеклы; *почтенный человек* — хөрмәтле кеше; 2. олы, зур; *почтенный возраст* — олы яшь; *статья весьма почтенных размеров* — шактый зур күләмдәге мәкалә.

**ПОЧТИ'** *нареч.*— ...диярлек, ...дисәң дә ярый; *он почти здоров* — ул сәламәт дияргә дә ярый.

**ПОЧТИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — ихтирам, хөрмәт; *он относился к матери с глубокой почтительностью* — ул әнисенә тирән ихтирам күрсәтә иде.

**ПОЧТИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. хөрмәтле, ихтирамлы; *почтительное отношение* — ихтирамлы мөнәсәбәт; 2. *разг. фам.* шактый зур; *почтительное расстояние* — шактый зур ара.

**ПОЧТИ'ТЬ** *сов. книж.*— хөрмәтләү, хөрмәт күрсәтү, ихтирам итү, олылау; олылап искә төшерү, хөрмәтләп искә алу.

**ПОЧТМЕ'ЙСТЕР** *м. офиц. истор.*— почтмейстер (почта конторасын идарә итүче чиновник).

**ПОЧТМЕ'ЙСТЕРСКИЙ** *офиц. истор.*— почтмейстер...-ы, почтмейстерлык...-ы; *почтмейстерская должность* — почтмейстер урыны, почтмейстер вазифасы.

**ПОЧТМЕ'ЙСТЕРША** *ж. разг. устар.*— почтмейстер хатыны.

**ПОЧТО'** *нареч. устар. обл.*— к. зачем.

**ПОЧТОВИ'К** *м. разг.*— почта хезмәтчесе; *клуб почтовиков* — почта хезмәтчеләре клубы.

**ПОЧТОВО'Й** — к. почтовый.

**ПОЧТО'ВО-ТЕЛЕГРА'ФНЫЙ** *офиц.*— почта һәм телеграф ... -ы; *почтово-телеграфная контора* — почта һәм телеграф конторасы.

**ПОЧТО'ВЫЙ** — почта...-ы; *почтовая марка* — почта маркасы. ◇ **Как на почтовых** — бик тиз (бару), ашыгып (бару); *мчится, как на почтовых* — бик тиз чаптырып бара.

**ПОЧУ'ВСТВОВАТЬ** *сов.*— сизү, тою, хис итү; *почувствовать себя лучше* — үзеңне яхшырак хис итү. ◇ **Дать почувствовать** — сиздерү, белдереп кую.

**ПОЧУ'ВСТВОВАТЬСЯ** *сов.*— сизелү, сизелеп китү; *с первого дня почувствовалось, что коллектив справится с работой* — коллективның эшне уңышлы башкарып чыгачагы беренче көннән үк сизелде.

**ПОЧУДА'ЧИТЬ** *сов. разг.*— бераз юләрләнеп алу, бераз шамакайланып алу, бераз шаярып алу.

**ПОЧУДИ'ТЬ** *сов. разг.*— юләрлекләр эшләп ташлау, әкәмәтләр эшләп ташлау, әкәмәтләр эшләү.

**ПОЧУ'ДИТЬСЯ** *сов. разг.*— ишетелгән кебек булу, күренгәнсыман булу.

**ПОЧУДИ'ТЬСЯ** *сов. обл.*— бераз шаккатып тору, бераз гаҗәпләнеп тору, бераз ис китеп тору.

**ПОЧУ'ЯТЬ** *сов. обл.*— сизеп алу, тою.

**ПОШАБА'ШИТЬ** *сов. простореч.*— эшне бетерү; *плотники пошабашили и пошли обедать* — балта осталары эшне бетерделәр дә төшке ашны ашарга киттеләр.

**ПОШАГА'ТЬ** *сов. разг.*— бераз (атлап) йөрү, бераз йөреп тору.

**ПОША'ЛИВАТЬ** *несов. разг.*— 1. шаяргалаштыру; *ребятишки стали пошаливать* — балалар шаяргалаштыра башладылар; 2. (*о лошади*) тынычсызлану; 3. *фам.* шаяргалау, авыртkалау; *сердце у меня пошаливает* — минем йөрәк авырткалый; 4. *перен. простореч.* шаяргалау (талау); *в лесу на большой дороге пошаливают разбойники* — урманда олы юлда юлбасарлар шаяргалый.

**ПОШАЛИ'ТЬ** *сов. разг.*— бераз шаярып алу, бераз шаяру; *пошалил, и будет* — бераз шаярып алдың — җитәр.

**ПОША'МКАТЬ** *сов. разг.*— бераз пышылдап кую, бераз пышылдау; *старик пошамкал губами* — карт иреннәре белән бераз пышылдап куйды.

**ПОША'РИТЬ** *сов. разг.*— кармалау, бераз актарыну; *пошарил в карманах и нашёл двугривенный* — кесәләрен кармалады да егерме тиен акча тапты.

**ПОША'РКАТЬ** *сов. разг.*— кыштырдатып алу, кыштырдатып кую; *пошаркать ногами* — аяклары белән кыштырдатып кую.

**ПОШАТА'ТЬ** *сов. разг.*— бераз какшатып алу, бераз селкетеп алу.

**ПОШАТА'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.*— 1. эшсез буталып йөрү; *целый день пошатался по городу* — көн буе шәһәрдә эшсез буталып йөрде; 2. селкенеп кую, тирбәлеп тору, селкенеп тору; *маятник пошатался несколько секунд* — сәгать теле берничә секунд селкенеп торды.

**ПОШАТНУ'ТЬ** *сов.*— 1. кыйшайтып кую, бәреп (төртеп) кыйшайту; *пошатнуть столб* — баганаlны кыйшайтып кую; 2. *перен.* какшатып җибәрү, какшатып кую, какшату; *пошатнуть здоровье* — сәламәтлекне какшату.

**ПОШАТНУ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. авып китә язу, егылып китә язу; *пошатнуться на ногах* — баскан җиреннән авып китә язу; 2. кыйшаю, кырыйаю; кыйшаеп китү; *забор пошатнулся от ветра* — койма җилдән кыйшаеп китте; 3. *перен. книж.* какшау; какшап китү; *в последнее время моё здоровье сильно пошатнулось* — соңгы вакытта минем сәламәтлегем бик нык какшап китте.

**ПОША'ТЫВАТЬ** *несов. разг.*— 1. чайкалдырып-чайкалдырып кую; *ветер пошатывает лодку* — җил көймәне чайкалдырып-чайкалдырып куя; 2. селкетеп-селкетеп кую; *ветер пошатывает забор* — җил койманы селкетеп-селкетеп куя. ◇ **Больного пошатывает от слабости** — авыру хәлсезлектән чак-чак аяк өстендә тора, авыру хәлсезлектән ава-түнә бара.

**ПОША'ТЫВАТЬСЯ** *несов. разг.*— алпантилпән килү, ава-түнә бару.

**ПО'ШВЫ** *ед.* нет, *обл.*— к. пошевни.

**ПОШВЫ'РИВАТЬ** *несов. разг.*— 1. ыргыткалау, вакыт-вакыт ыргыту; *пошвыри-*

*вать камни в реку* — елгага таш ыргыткалау; 2. туздыргалау; *пошвыривать деньгами* — акча туздыргалау.

**ПОШВЫ'РИВАТЬСЯ** *несов. разг. фам.* — 1. к. пошвыривать; 2. *перен.* (*пренебрегать*) санга сукмау, исәпкә алмау.

**ПОШВЫРЯ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. ташлап бетерү, ыргытып бетерү; *пошвырять все книги в ящик* — барлык китапларны ящикка ыргытып бетерү; 2. бераз ыргыту, ташлау; *пошвырять камнями* — бераз ташлар ыргыту.

**ПОШВЫРЯ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. атышу, ыргытышу; *пошвыряться камнями* — таш ыргытышу; 2. туздыру, бераз туздырып алу; *пошвыряться деньгами* — бераз акча туздырып алу.

**ПОШЕВЕ'ЛИВАТЬ** *несов. разг.* — 1. кузгаткалау, селкеткәләү, кыймылдаткалау; селкетеп-селкетеп кую, кыймылдатып (кузгатып) кую; *пошевеливать вожжами* — дилбегәне селкетеп-селкетеп кую; 2. болгаткалау, болгатып-болгатып кую; *пошевеливать ложкой в кастрюле* — кастрюльне кашык белән болгатып-болгатып кую. ◇ **Пошевеливай** *фам.* — тизрәк кыймылда, тизрәк бул.

**ПОШЕВЕ'ЛИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — вакыт-вакыт кыймылдап кую. ◇ **Пошевеливайся** — тизрәк кыймылда, тизрәк бул.

**ПОШЕВЕЛИ'ТЬ** *сов.* — кыймылдату, кузгату.

**ПОШЕВЕЛИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — кыймылдау, кыймылдап кую; *так тесно, что и пошевелиться невозможно* — шул кадәр тыгыз (кысан), кыймылдар хәл дә юк.

**ПОШЕВЕЛЬНУ'ТЬ** *сов. разг.* — кыймылдатып кую, кыймылдату, кузгатып кую, кузгату; *она и пальцем не пошевельнёт, чтобы вас избавить* (*Тургенев*) — сезне коткару өчен ул бармак та кыймылдатмас.

**ПОШЕВЕЛЬНУ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — кыймылдау, кузгалу, селкенү; *он и пошевельнуться не может* — ул кузгала да алмый. ◇ **И не пошевельнуться** — берниндн ярдәм дә итмәү; кыл да кыймылдатмау; *он и не пошевельнулся, видя её горе* — аның кайгысын күреп, ул берниндн ярдәм дә итмәде.

**ПО'ШЕВНИ** *ед.* нет, *обл.* — утын чанасы, тәрәкле чана.

**ПО'ШЕПТ** *м. обл.* — 1. пышылдау, пышылдап сөйләү; 2. (*заговор, заклинание*) өшкерү, әфсен уку.

**ПОШЕПТА'ТЬ** *сов.* — пышылдап сөйләү, пышылдап әйтү, бераз пышылдап алу.

**ПОШЕПТА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — пышылдашып сөйләшеп алу.

**ПО'ШЕПТУ** *нареч. обл.* — пышылдап; *ответил Архип пошепту* — Архип пышылдап җавап бирде.

**ПОШЕХО'НЕЦ** *м. публ.* — пошехонец (надан, артка калган, аңгыра обыватель).

**ПОШИ'Б** *м. мн.* нет, *разг.* — стиль, манера, алым, рәвеш. ◇ **Одного пошиба** — бертөсле, бер чыбыктан сөрелгән.

**ПОШИ'В** *м. мн.* нет, *спец. простореч.* — к. пошивка.

**ПОШИВА'ТЬ** *несов. простореч.* — теккәләштерү, аз-маз теккәләштерү.

**ПОШИ'ВКА** *ж. мн.* нет, *спец.* — тегү.

**ПОШИ'ВОЧНЫЙ** *спец.* — тегү...-ы; *пошивочная мастерская* — тегү мастерское.

**ПОШИ'ВЩИК** *м.*, **ПОШИ'ВЩИЦА** *ж. спец.* — тегүче.

**ПОШИ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. бераз тегеп алу, тегеп алу; *пошить с часок* — бер сәгать чамасы тегеп алу; 2. күп итеп тегү; *пошить костюмы* — күп итеп костюмнар тегү.

**ПОШЛЁПАТЬ** *сов. разг. фам.* — 1. шап иттереп сугу, шапылдатып сугып алу; *пошлёпать по спине* — аркасына шапылдатып сугып алу; 2. лач-лоч басып китеп бару; *пошлёпали по грязи* — пычракка лач-лоч басып китеп бардылар.

**ПОШЛЕ'ТЬ** *несов.* — әшәкеләнә бару, бозыла бару, бозыклыкка бирелә башлау.

**ПОШЛЕ'Ц** *м. разг. презр. устар.* — бозык кеше, кабахәт кеше.

**ПО'ШЛИНА** *ж. экон.* — пошлина (читкә чыгарыла һәм читтән кертелә торган товарларга, милекләргә салына торган налог, акчалата җыем).

**ПО'ШЛИННЫЙ** *экон.* — пошлина...-ы; *пошлинный устав* — пошлина уставы.

**ПО'ШЛОСТЬ** *ж.* — 1. *только ед.* әшәкелек, кабахәтлек; 2. әшәке сүз, әшәке кыланыш; *говорить пошлости* — әшәке сүзләр сөйләү.

**ПО'ШЛЫЙ** — әшәке, шакшы, бозык, кабахәт; *пошлый человек* — бозык кеше.

**ПОШЛЯ'К** *м.*, **ПОШЛЯ'ЧКА** *ж. разг. презрит.* — оятсыз кеше, кабахәт кеше, әшәке кеше, пычрак кеше.

**ПОШЛЯ'ТИНА** *ж. мн.* нет, *разг. презрит.* — әшәкелек, бозыклык.

**ПОШЛЯ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — эшсез йөрү, тырай тибеп йөрү (бераз).

**ПОШТО'** — к. почто.

**ПОШТУ'ЧНЫЙ** *спец.* — 1. данә башыннан...-а торган, данәләп...-а торган; *поштучная заработная плата* — данә башыннан түләнә торган эш хакы; 2. берәмләп; *поштучная продажа* — берәмләп сату.

**ПОШУМЕ'ТЬ** *сов.* — бераз тавышланып алу, бераз шаулап алу.

**ПОШУТИ'ТЬ** *сов.* — шаяру, шаярып алу, бераз шаярып алу; *он любит пошутить* — ул шаярырга ярата.

**ПОШУ'ЧИВАТЬ** *несов. разг.* — вакыт-вакыт шаяру, шаяргалаштыру.

**ПОЩА'ДА** *ж. мн.* нет — шәфкать, аяу, мәрхәмәт; *просить пощады* — мәрхәмәт сорау; *без пощады* — аяусыз; *не давать пощады врагу* — дошманга шәфкать күрсәтмәү.

**ПОЩАДИ'ТЬ** *сов.* — 1. аяу, кызгану; *для науки я не пощажу жизни* — фән өчен мин җанымны кызганмам; 2. саклау, саклап калу (җимерелүдән, искерүдән); *время не пощадило этого здания* — вакыт бу бинаны җимерелүдән саклап кала алмаган; *пощади своё здоровье* — үзеңнең сәламәтлегеңне сакла.

**ПОЩЕГОЛЯ'ТЬ** *сов. разг.* — купшыланып йөрү, көязләнеп йөрү (берникадәр вакыт).

**ПОЩЕКОТА'ТЬ** *сов.*— кытыклау, кытыклап алу, кытыклап карау.

**ПОЩЁЛКАТЬ** и **ПОЩЕЛКА'ТЬ** *сов. разг.*— 1. шартлатып алу; *пощёлкать языком* — тел шартлатып алу; 2. *фам.* (*надавать щелчков, побить*) чиртү, чирткәләү, дөмбәсләп алу, тукмап алу. ◇ **Пощёлкать орехов** — шарт-шорт ватып чикләвек ашап алу.

**ПОЩЁЛКИВАТЬ** *несов. разг.*— тукылдаткалау, вакыт-вакыт тукылдату (тукран); вакыт-вакыт чут-чут итеп сайрау (сандугач); вакыт-вакыт шартлату (бармак, чыбыркы һ. б.); чалт иткәләү, вакыт-вакыт чалт итү (берәр нәрсәне ачып япканда).

**ПОЩЕПА'ТЬ** *сов. разг.*— телү, телеп алу, бераз телү; *пощепать лучины* — бераз чыра телү.

**ПОЩЁЧИНА** *ж*— 1. (*удар по щеке*) яңаклау, чабып җибәрү, яңакка сугу; 2. *перен.* (*оскорбление, обида*) мәсхәрәләү, мыскыл итү, хурлау; *пощёчина общественному вкусу* — җәмгыятьтә кабул ителгән гадәтләрне мыскыл итү.

**ПОЩИПА'ТЬ** *сов.*— 1. чеметкәләп кую, тарткалап кую, чеметкәләү, чеметеп-чеметеп алу; *он пощипал усы* — ул мыекларын чеметкәләп (тарткалап) куйды; 2. *разг.* чуку, йолку (үләнне), ашап бетерү; *овцы пощипали всю траву* — сарыклар барлык үләнне ашап бетергәннәр; 3. *разг. фам. шутл.* чеметкәләп алу, тәнкыйтьләп алу; *пощипать бюрократов* — бюрократларны чеметкәләп алу; 4. *простореч. шутл.* (*пограбить*) талау, талап алу.

**ПОЩИ'ПЫВАТЬ** *несов. разг.*— чеметкәләштерү, сирәк-мирәк чеметү, тарткалау.

**ПОЩУ'ПАТЬ** *сов.*— 1. тотып карау, капшап карау, кармалап карау; *пощупать пульс* — пульсны тотып карау; 2. *перен. разг фам.* сынап карау, тикшереп карау; *пощупать знания нового ученика* — яңа укучының белемен сынап карау.

**ПОЩУ'ПЫВАТЬ** *несов. разг.*— вакыт-вакыт капшап карау, кармалаштыру.

**ПОЩУ'РИВАТЬ** *несов. разг.*— (вакыт-вакыт) кыскалау; *пощуривать глаза* — күз кыскалау.

**ПОЩУ'РИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— күз кысу, күзне йома төшеп карау.

**ПОЩУ'РИТЬ** *сов.*— бераз күз кысып карап тору.

**ПОЩУ'РИТЬСЯ** *сов.*— к. пощурить.

**ПОЭ'ЗИЯ** *ж. мн.* нет — 1. поэзия (матур әдәбиятның шигырь белән язылган төре); *советская поэзия* — совет поэзиясе; *поэзия Тукая* — Тукай поэзиясе; 2. *перен. книж.* нәфислек, гүзәллек, зифалык, матурлык, шигърият; *поэзия летнего утра* — җәйге таңның гүзәллеге, җәйге таңның шигърияте; 3. *перен. устар. ирон.* (*мир фантазии*) хыял дөньясы, хыял.

**ПОЭКЗАМЕНОВА'ТЬ** *сов. разг.*— белемен тикшереп карау, экзаменовать итеп карау.

**ПОЭКЗАМЕНОВА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— экзамен бирү, экзамен тоту, имтихан бирү, имтихан тоту, имтихан тапшыру.

**ПОЭ'МА** *ж.*— поэма (1. шигырь белән язылган зур әдәби әсәр; 2. *перен. разг. шутл. устар.* искиткеч бер нәрсә, шаккатарлык бер нәрсә; *вид на Кавказский хребёт при восходе солнца — эта целая поэма!* — кояш чыкканда Кавказ тауларының күренеше — бер поэма ул! 3. *муз.* кайбер музыкаль әсәрләрнең исеме).

**ПОЭСКАДРО'ННО** *нареч. воен.*— эскадронлап, эскадрон-эскадрон булып; *полк вступил в город поэскадронно* — полк шәһәргә эскадрон-эскадрон булып керде.

**ПОЭ'Т** *м.*— шагыйрь.

**ПОЭТИЗИ'РОВАТЬ** *сов. книж.*— поэтик төсләрдә күрсәтү, матур итеп күрсәтү, шигъри итеп күрсәтү; *поэтизировать действительность* — чынбарлыкны поэтик төсләрдә күрсәтү.

**ПОЭТИЗИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. книж.*— шигърилләштерелү, поэтиклаштырылу.

**ПОЭ'ТИКА** *ж. лит.*— поэтика (1. матур әдәбият теориясе; 2. поэзия теориясе; 3. берәр шагыйрьнең яки әдәби юнәлешнең поэтик формалары һәм принциплары системасы).

**ПОЭТИ'ЧЕСКИЙ** — 1. поэзия...-ы; поэтик, шигъри; *поэтическое произведение* — поэтик әсәр; 2. *перен. книж.* матур, гүзәл, шигъриятле; *поэтический вид* — гүзәл күренеш, шигъриятле күренеш; 3. *перен. устар.* (*идеальный*) идеаллаштырылган; 4. *пренебр. устар.* (*приукрашенный фантазией*) хыяллаштырылган. ◇ **Поэтическая жилка** — шигъри сәләт; *у него есть поэтическая жилка* — аның шигъри сәләте бар.

**ПОЭТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— шигъриятлелек, шигърилек.

**ПОЭТИ'ЧНЫЙ** *книж.* — к. поэтический 2, 3.

**ПОЭ'ТОМУ** *нареч.*— 1. шуның өчен, шунлыктан, шуңа күрә; *я спешил, поэтому и не подождал тебя* — мин ашыга идем, шуңа күрә сине көтеп тора алмадым; 2. *разг.* (*значит, следовательно*) димәк, шулай булгач.

**ПОЯВИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. килү, килеп чыгу; *появиться в новом костюме* — яңа костюм киеп килү; 2. күренү; *вдали появились огоньки деревни* — еракта авылның утлары күренде; 3. *перен.* барлыкка килү, туу; *появились новые затруднения* — яңа кыенлыклар туды; *появились новые города* — яңа шәһәрләр барлыкка килде.

**ПОЯВЛЕ'НИЕ** *ср.*— к. появиться.

**ПОЯВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— к. появиться.

**ПОЯ'РКОВЫЙ** — бәрән йонынан эшләнгән; *поярковая шляпа* — бәрән йонынан эшләнгән эшләпә.

**ПОЯ'РОК** *м. мн.* нет, *спец.*— бәрән йоны.

**ПО'ЯС** *м.*— 1. билбау, бил каешы; *красный пояс* — кызыл билбау; 2. *простореч.* бил; *стоять по пояс в воде* — билдән суда басып тору; 3. *геогр.* пояс; *жаркий пояс* — эссе пояс; 4. *экон.* пояс; *тарифный пояс* — тариф поясы; 5. *устар.* (*хребет, цепь гор*) сырт; *горный Уральский пояс* — Урал тау-

гары сырты; 6. *тех.* кыршау; *пояс баржи* — баржа кыршавы. ◇ **Заткнуть за пояс** — к. заткнуть. **Кланяться в пояс** — бөгелеп сәлам бирү, бик түбән иелеп сәлам бирү.

**ПОЯСНЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *книж.* ачыкландыру, аңлату, аңлатып бирү; 2. аңлатма; *прочитать пояснения к рисункам* — рәсемнәргә бирелгән аңлатмаларны укып чыгу.

**ПОЯСНИ'ТЕЛЬ** *м. книж.* — аңлатучы, аңлатып бирүче.

**ПОЯСНИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — аңлатма...-ы, ачыклау...-ы; *пояснительный текст* — ачыклау тексты.

**ПОЯСНИ'ТЬ** *сов.* — аңлату, аңлатып бирү, ачыклап бирү.

**ПОЯСНИ'ЦА** *ж.* — бил.

**ПОЯСНИ'ЧНЫЙ** *анат.* — бил...-ы; *поясничная мышца* — бил мускулы.

**ПОЯСНО'Й** — 1. бил...-ы; *поясной ремень* — бил каешы; 2. билгә кадәр төшерелгән; *поясной портрет* — билгә кадәр төшерелгән портрет; 3. пояс...-ы; *поясное время* — пояс вакыты.

**ПОЯСНЯ'ТЬ** *несов.* — к. пояснить.

**ПОЯСНЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — аңлатып бирелү, аңлатылу.

**ПРАБА'БКА** *ж.*, **ПРАБА'БУШКА** *ж.* — әбисенең әнисе, бабасының әнисе, ерак әби.

**ПРА'ВДА** *ж. мн.* нет — 1. дөрес, дөреслек, чын, хакыйкать; *говорить правду* — дөресен сөйләү; 2. *в знач. сказ. разг.* дөрес, хак, чын; *говорят, что вы уезжаете, правда ли это?* — сезне китә диләр, дөресме? 3. *в знач. ввод. слова* чыннан да, чынлап та, дөрестән дә; *я, правда, не знал этого* — мин, чынлап та, моны белмәгән идем; 4. *в знач. уступительного союза* хәер, дөрес, чыннан да; *правда, это пальто немножко дорого, но зато прочно* — дөрес, бу пальто бераз кыйммәтрәк, ләкин нык. ◇ **Всеми правдами и неправдами** — төрле юллар белән, чыны-ялганы белән. **По правде говоря или правду говоря** — дөресен әйткәндә. **Не правда ли** — шулай түгелмени, шулай бит. **Правда глаза колет** — туры әйткән туганына ярамаган.

**ПРАВДИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — чынлык, дөреслек, турылык, туры сүзлелек.

**ПРАВДИ'ВЫЙ** — 1. дөрес, чын, хак; *правдивое известие* — дөрес хәбәр; 2. туры, туры сүзле, дөреслекне ярата торган, гадел; *правдивый человек* — дөреслекне ярата торган кеше, туры кеше, гадел кеше, туры сүзле кеше.

**ПРАВДИ'СТ** *м. истор.* — 1. правдист (1912—1914 елларда большевиклар газетасы „Правда" чыккан чакта большевиклар шулай дип исемләнәләр иде); 2. „Правда" газетасы работнигы.

**ПРАВДОЛЮБИ'ВЫЙ** *книж. устар.* — дөреслекне яратучан, гадел; *правдолюбивый человек* — дөреслекне яратучан кеше.

**ПРАВДОЛЮ'БИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — дөреслекне (гаделлекне, хакыйкатьне) ярату.

**ПРАВДОПОДО'БИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — дөреска охшашлык, чынга охшашлык.

**ПРАВДОПОДО'БНЫЙ** *книж.* — дөрескә охшаган, ышанырлык; *правдоподобный рассказ* — дөрескә охшаган хикәя.

**ПРА'ВЕДНИК** *м.*, **ПРА'ВЕДНИЦА** *ж. книж. устар.* — 1. *рел.* тәкъва кеше; 2. әхлаклы кеше, хыянәтсез яшәүче кеше.

**ПРА'ВЕДНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж. устар.* — 1. *рел.* тәкъвалык; 2. турылыклылык, гаделлек.

**ПРА'ВЕДНЫЙ** *книж. устар.* — 1. *рел.* тәкъва; 2. турылыклы, гадел, хыянәтсез.

**ПРАВЁЖ** *м. истор.* — таяк белән кыйнау, суктыру (борынгы Русьта: бурычын түли алмаган өчен таяк белән кыйнау).

**ПРАВЕ'ТЬ** *несов.* — уңлашу, уңлаша бару (политик мәсьәләләрдә).

**ПРА'ВИЛО** *ср.* — 1. кагыйдә; тәртип, куелган тәртип; *грамматическое правило* — грамматик кагыйдә; *правила внутреннего распорядка* — эчке тәртип кагыйдәләре; *нарушать правила* — тәртипне бозу; 2. *преимущ. мн.* (*принцип поведения*) кагыйдә, гадәт; *взять себе что-н. за правило* — берәр нәрсәне үзеңә гадәт итеп алу. ◇ **По всем правилам искусства** *разг.* — жиренә җиткереп. **Как правило** — кагыйдә буларак.

**ПРАВИ'ЛО** *ср. спец.* — 1. тигезләгеч (мич чыгарганда, кирпеч йорт салганда тигезлекне билгеләү өчен кулланыла торган агач линейка); 2. *сапож.* (*колодка*) аяк киеме калыбы; 3. *охот.* (*хвост у борзой собаки*) бурзай эт койрыгы; 4. *мор. устар.* көймә койрыгы, судно койрыгы.

**ПРА'ВИЛЬНО** *нареч.* — дөрес.

**ПРА'ВИЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — дөреслек.

**ПРА'ВИЛЬНЫЙ** — 1. дөрес; *правильное рассуждение* — дөрес уйлау, дөрес фикер йөртү; 2. регуляр, тәртипле; *правильное движение поездов* — поездларның регуляр йөреше. ◇ **Правильный нос** — туры борын. **Правильный многоугольник** *мат.* — төзек күппочмак. **Правильный многогранник** *мат.* — төзек күпкырлык. **Правильная дробь** *мат.* — ялгыз вакланма. **Правильные черты лица** — йөзенең килешле булуы, йөзенең килешлелеге.

**ПРАВИ'ЛЬНЫЙ** *спец.* — төзәтү...-ы; тигезләгеч дөресләү..-ы; *правильная плита* — тигезләгеч дөресләү плитасы.

**ПРАВИ'ЛЬЩИК** *м. спец.* — хаталарны төзәтүче (типографиядә).

**ПРАВИ'ТЕЛЬ** *м. книж.* — 1. хөкүмәт башлыгы, илне идарә итүче; 2. *офиц. дореволюц.* управляющий, мөдир, башлык; *правитель канцелярии* — канцелярия башлыгы.

**ПРАВИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж.* — к. правитель 1.

**ПРАВИ'ТЕЛЬСТВЕННЫЙ** *офиц.* — 1. хөкүмәт...-ы; *правительственные учреждения* — хөкүмәт учреждениеләре; 2. хөкүмәт...-ы, хөкүмәт тарафыннан бирелгән, хөкүмәт тарафыннан чыгарылган; *правительственное решение* — хөкүмәт карары, хөкүмәт тарафыннан чыгарылган карар.

**ПРАВИ'ТЕЛЬСТВО** *ср.* — хөкүмәт; *глава правительства* — хөкүмәт башлыгы.

**ПРА'ВИТЬ** *несов.* — 1. *устар.* (*управ-*

*лять, руководить)* идарә итү, житәкчелек итү; 2. тоту, йөртү; *править лошадьми* — ат тоту; *править лодкой* — көймә койрыгын тоту; *править судном* — судноны йөртү; 3. төзәтү; *править ошибки* — хаталарны төзәтү; 4. *спец.* урынына утырту; *править руку* — (каймыккан) кулны урынына утырту; 5. *спец.* тигезләү, турайту; *править листы железа* — калай табакларын тигезләү; 6. *спец.* үткенләү, беләүгә тоту; *править бритву* — бритваны беләүгә тоту; 7. *устар.* (*совершать, исполнять*) үтәү, башкару, үткәрү.

**ПРА'ВКА** *ж. спец.* — к. править 3, 4, 5.

**ПРАВЛЕ'НЕЦ** *м. разг.* — идарә члены.

**ПРАВЛЕ'НИЕ** *ср. книж.* — 1. идарә итү; *форма правления* — идарә итү формасы; 2. идарә, правление; *правление артели* — артель идарәсе; *правление колхоза* — колхоз идарәсе.

**ПРА'ВЛЕНЫЙ** — төзәтелгән; *правленая рукопись* — төзәтелгән кулъязма.

**ПРА'ВНУК** *м.*, **ПРА'ВНУЧКА** *ж.* — баланың баласының баласы.

**ПРА'ВО** I *ср.* — 1. *право* хокук; *избирательное право* — сайлау хокукы; *право на отдых* — ял итүгә хокук; *право голоса* — тавыш бирү хокукы; *поражение в правах* — хокуктан мәхрүм итү; *восстановить в правах* — хокукын кайтарып бирү; *право на наследство* — варислык хокукы; 2. *только ед.* (*наука о законодательстве*) хокук турындагы фән; 3. хак; *по какому праву?* — ни хакың бар? *я не имею права так поступать* — минем алай эшләргә хакым юк; 4. нигез, сәбәп; *с полным правом могу сказать так* — алай әйтергә тулы нигезем бар.

**ПРА'ВО** II *ввод. сл.* — чынлап та, чыннан да, дөрестән дә; *я, право, не знаю, что мне делать* — чыннан да, мин нәрсә эшләргә дә белмим. ◇ Право слово *простореч.* — чынлап әйтәм, хак сүз; *право слово, не опоздаю* — чынлап әйтәм, сонга калмам.

**ПРАВОБЕРЕ'ЖНЫЙ** — уң як ярдагы, елганың уң ягындагы, уң яр буендагы; *правобережная Украина* — Украинаның Днепр елгасыннан уң яктагы өлеше.

**ПРАВОВЕ'Д** *м. книж.* — хокук белгече.

**ПРАВОВЕ'ДЕНИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — хокук белеме, хокук турындагы фән.

**ПРАВОВЕ'РНЫЙ** *книж.* — 1. дингә нык ышанучы; *правоверный католик* — нык ышанучы католик; 2. *перен.* бик нык ышанучы, ихлас; *правоверный гегельянец* — ихлас гегельче.

**ПРАВОВИ'К** *м. разг.* — хокук белгече, хокук белеме галиме, юрист.

**ПРАВОВО'Й** — хокук ...-ы; *правовые нормы* — хокук нормалары; *правовые отношения* — хокук мөнәсәбәтләре.

**ПРАВОЗАСТУ'ПНИК** *м. истор.* — (судта) җәмәгать гаепләүчесе, җәмәгать яклаучысы.

**ПРАВОМЕ'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — законлылык.

**ПРАВОМЕ'РНЫЙ** *книж.* — нигезле, дәлилле, урынлы, законлы; *правомерный вывод* — нигезле нәтиҗә, урынлы нәтиҗә.

**ПРАВОМО'ЧИЕ** *ср. право* — хокуклы булу, тулы хокуклылык.

**ПРАВОМО'ЧНЫЙ** *юр.* — тулы хокуклы; *он вполне правомочен это сделать* — ул бу эшне эшләргә тулы хокуклы.

**ПРАВОНАРУШЕ'НИЕ** *ср. право* — хокукны бозу, хокук кагыйдәләренә каршы килү, закон бозу.

**ПРАВОНАРУШИ'ТЕЛЬ** *м. право* — җинаятьче, закон бозучы.

**ПРАВООППОРТУНИСТИ'ЧЕСКИЙ** *полит.* — уң оппортунистларча...; уң оппортунистлык...-ы; *правооппортунистические взгляды* — уң оппортунистларча карашлар.

**ПРАВОПИСА'НИЕ** *ср. грам.* — орфография, дөрес язу.

**ПРАВОПИ'СНЫЙ** *книж.* — орфографик.

**ПРАВОПОРАЖЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *право* — хокуктан мәхрүм итү.

**ПРАВОПОРЯ'ДОК** *м. книж.* — хокук тәртибе, закон тәртибе.

**ПРАВОПРОИЗНОШЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *лингв.* — дөрес әйтелеш, орфоэпия.

**ПРАВОСЛА'ВИЕ** *ср. мн.* нет, *церк.* — православие (христиан диненең бер төре).

**ПРАВОСЛА'ВНЫЙ** — 1. православие...-ы; *православная вера* — православие дине; 2. православие динендәге кеше.

**ПРАВОСОЗНА'НИЕ** *ср. книж.* — хокук аңы (кешелек җәмгыяте бәхете өчен хокук нормаларын үтәүнең кирәклеген аңлау).

**ПРАВОСПОСО'БНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *право* — хокукка ия булу, хокуклы булу.

**ПРАВОСПОСО'БНЫЙ** *юр.* — хокуклы, үзенең эшләре өчен җаваплы; *правоспособное лицо* — хокуклы кеше, үзенең эшләре өчен җаваплы кеше.

**ПРАВОСУ'ДИЕ** *ср. мн.* нет — 1. *офиц.* гадел хөкем, туры хөкем; 2. суд органнарының эшчәнлеге, юстиция.

**ПРАВОСУ'ДНЫЙ** *право, книж.* — гадел хөкемгә нигезләнгән.

**ПРАВОТА'** *ж. мн.* нет — турылыклылык, гаделлек, хаклык, дөреслек.

**ПРАВОФЛАНГО'ВЫЙ** — уң флангтагы (уң якта торучы); *правофланговый солдат* — уң флангтагы солдат.

**ПРА'ВЩИК** *м. тип.* — к. правильщик 1.

**ПРА'ВЫЙ** I — 1. уң; *правая рука* — уң кул; 2. *полит.* уң, реакцион, консерватив; *правая партия* — уң партия; 3. уң (марксизм-ленинизмга, коммунистлар партиясенә, совет хөкүмәтенә дошман); *правый уклон* — уң тайпылыш; *правая оппозиция* — уң оппозиция; 4. *в знач. сущ.* уң (консерватив, реакцион фикерле кеше).

**ПРА'ВЫЙ** II — 1. гөнаһсыз, гаепсез; *защищать правого* — гаепсез кешене яклау; 2. гадел, изге, хак; *наше дело правое* — безнең эш хак, безнең эшебез хак эш; 3. *книж. устар.* дөрес; *правое мнение* — дөрес фикер; 4. *в знач. сказ.* хаклы; *вы совершенно правы* — сез һичшиксез хаклы.

**ПРА'ВЯЩИЙ** — хакимлек итүче, идарә башында торучы, житәкче, житәкчелек итүче; *правящие круги* — житәкчелек итүче даирәләр.

**ПРАГМАТИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *филос. науч.*— прагматизм (1. буржуаз идеалистик философиядә чынбарлыкның объектив законнарын танып-белү мөмкинлеген инкарь итә торган һәм буржуазиягә гамәлдә файда китерә торган нәрсәләрне генә хакыйкать дип саный торган реакцион субъектив-идеалистик агым; 2. тарихта аерым вакыйгаларның тарихи эчтәлеген ачып бирмичә, аларның тышкы бәйләнешләрен һәм тышкы эзлеклелеген генә күздә тотып тасвирлау).

**ПРАГМА'ТИК** *м.*, **ПРАГМАТИ'СТ** *м. книж.*— прагматик (прагматизм тарафдары).

**ПРАГМАТИ'ЧЕСКИЙ** — прагматик; *прагматическая философия* — прагматик философия.

**ПРАГМАТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— прагматиклык.

**ПРАГМАТИ'ЧНЫЙ** *книж.*— к. прагматический.

**ПРА'ДЕД** *м.*— 1. бабаның яки әбинең атасы; 2. *только мн.* ата-бабалар.

**ПРАДЕ'ДОВСКИЙ** — ата-бабалар ...-ы; *прадедовские времена* — ата-бабалар заманы.

**ПРАДЕ'ДУШКА** *м. разг.*— к. прадед.

**ПРА'ЗДНЕСТВО** *ср. книж. ритор.*— тантаналы бәйрәм, бәйрәм, тантана.

**ПРА'ЗДНИК** *м.*— 1. бәйрәм; 2. *(день отдыха)* ял көне; 3. *(веселье, бал)* кичә, бал. ◇ **Быть у праздника** *разг.* — бәйрәмгә катнашу. **С праздником!** — бәйрәм котлы булсын! бәйрәм белән! **На душе праздник** — кәеф бик яхшы, күңел шат.

**ПРА'ЗДНИЧАТЬ** *несов. разг. устар.*— 1. бәйрәм мәжлесе кору; 2. *перен. (бездельничать)* эшсез йөрү.

**ПРА'ЗДНИЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— бәйрәмчәлек, бәйрәмчә булу; *праздничность вида* — кыяфәтнең бәйрәмчә булуы; *праздничность одежды* — киемнең бәйрәмчәлеге, киемнең бәйрәмчә булуы.

**ПРА'ЗДНИЧНЫЙ** — 1. бәйрәм ...-ы; *праздничный обед* — бәйрәм ашы; 2. *перен.* тантаналы, шатлыклы; *праздничный вид* — шатлыклы кыяфәт.

**ПРА'ЗДНОВАНИЕ** *ср. книж.* — бәйрәм итү.

**ПРА'ЗДНОВАТЬ** *несов.* — бәйрәм итү. ◇ **Труса праздновать** — курку, шүрләү.

**ПРАЗДНОЛЮБИ'ВЫЙ** *книж. устар.*— ялкау, тик торырга яратучан, эшсез йөрергә яратучан.

**ПРАЗДНОСЛО'ВИЕ** *ср. мн.* нет, *церк., книж. устар.*— буш сүзләр.

**ПРАЗДНОСЛО'ВНЫЙ** *книж. устар.*— буш сүзле; буш сүзләр сөйләүче, буш сүзләр сөйләргә яратучан; *празднословный человек* — буш сүзләр сөйләүче кеше.

**ПРА'ЗДНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— 1. мәгънәсезлек; *праздность разговора* — сөйләшүнең мәгънәсезлеге; 2. *(безделье)* эшсезлек, тик яту, гамьсез яшәү.

**ПРАЗДНОШАТА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *фам. устар.*— эшсез йөрү, тик йөрү, тырай тибү.

**ПРАЗДНОШАТА'ЮЩИЙСЯ** *разг. фам.*— тик йөрүче, эшсез йөрүче, тырай тибеп йөрүче.

**ПРА'ЗДНЫЙ** — 1. *книж. поэт. устар. (пустой, порожний)* буш; 2. эшсез; *праздное шатание по городу* — шәһәр буйлап эшсез йөрү; 3. буш, мәгънәсез; *праздный разговор* — мәгънәсез сөйләшү; 4. нәтиҗәсез, буш, мәгънәсез; *праздные попытки* — нәтиҗәсез маташулар. ◇ **Праздная болтовня** — сафсата, ләчтит сату.

**ПРАКРИ'Т** *м. мн.* нет, *собир, лингв.*— пракрит (Урта Индиянең халык диалектлары).

**ПРАКРИ'ТСКИЙ** *лингв.* — пракрит ...-ы; *пракритские диалекты* — пракрит диалектлары.

**ПРА'КТИК** *м.*— тәҗрибәле кеше, практик.

**ПРА'КТИКА** *ж. мн.* нет — 1. практика; *всегда сочетать теорию с практикой* — теорияне һәрвакыт практика белән бәйләргә; *летняя практика студентов* — студентларның җәйге практикасы; 2. эш, тәҗрибә; *практика составления словарей* — сүзлекләр төзү тәҗрибәсе. ◇ **Применить на практике** — тормышта куллану. **Медицинская практика** — медицина белән шөгыльләнү. **Частная практика** — хосусый практика, өйдә эшләү, өйдә кабул итү (мәсәлән, врач, юрист һ. б.).

**ПРАКТИКА'НТ** *м.*— практикант, практика үтүче.

**ПРАКТИКА'НТСКИЙ** — практикант... -ы, практикантлар ...-ы; *практикантская работа* — практикантлар эше.

**ПРАКТИКА'НТСТВО** *ср. мн.* нет, *спец.*— практикантлык.

**ПРАКТИКОВА'ТЬ** *несов.* — 1. куллану; *практиковать новый метод работы* — эштә яңа метод куллану; 2. эшләү, үз эшен алып бару; *этот врач практикует уже двадцать лет* — бу врач егерме ел эшли инде.

**ПРАКТИКОВА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. тәҗрибә алу, өйрәнү; тәҗрибәләр ясау; *чтобы изучить технику дела, надо практиковаться* — эшнең техникасын белү өчен тәҗрибәләр ясарга кирәк; 2. *страд.* кулланылу.

**ПРА'КТИКУМ** *м. книж. педаг.* — практикум (берәр фәнне үзләштерү өчен үткәрелә торган практик занятиеләр).

**ПРАКТИЦИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.*— практицизм (1. тормышны яки берәр эшне уңышлы итеп куя белү; 2. практиканы теориядән өстен кую, практик эшкә генә бирелеп, теориягә әһәмият бирмәү).

**ПРАКТИ'ЧЕСКИЙ** *книж.*— практик ...; *практическая деятельность* — практик эшчәнлек; *практический опыт* — практик тәҗрибә; *практические занятия* — практик дәресләр.

**ПРАКТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— 1. унайлык, җайлылык; *практичность способа* — ысулның унайлыгы; 2. *(деловитость)* эшлеклелек, булдыклылык, тәҗрибәлелек.

**ПРАКТИ'ЧНЫЙ** — 1. булдыклы, эшлекле, тәҗрибәле; *практичный человек* — тәҗрибәле кеше; 2. уңайлы, эшкә яраклы; *практичный способ* — уңайлы ысул.

**ПРАМА'ТЕРЬ** *ж. книж. ритор. устар.*— ыруг башлыгы ана (берәр буынның, нәселнең ыруг башлыгы анасы).

**ПРА'ОТЕЦ** *м. книж. устар.*— ыруг башлыгы ата (берәр буынның ыруг башлыгы атасы). ◇ **Отправиться к праотцам** *разг. шутл.*— үлү. **Отправить к праотцам** *разг. шутл.*— үтерү.

**ПРАОТЦО'ВСКИЙ** *книж. устар.* — ата-бабалар...-ы; *праотцовские обычаи* — ата-бабалар йоласы.

**ПРА'ПОРЩИК** *м.*— прапорщик (патша армиясендә иң кече офицерлык чины).

**ПРА'ПОРЩИЦКИЙ** *доревол.* — прапорщик...-ы, прапорщиклар...-ы; *прапорщицкие погоны* — прапорщиклар погоны.

**ПРАПРАБА'БКА** *ж.*, **ПРАПРАБА'БУШКА** *ж.*— әбинең яки бабайның әбисе.

**ПРАПРА'ВНУК** *м.*— оныкның улының яки кызының улы.

**ПРАПРА'ВНУЧКА** *ж.*— оныкның улының яки кызының кызы.

**ПРАПРА'ДЕД** *м.*— бабайның яки әбинең бабасы.

**ПРАРО'ДИНА** *ж. ритор.*— беренче торган җир (берәр кабиләнең, хайван яки үсемлекләрнең иң борынгы ватаны).

**ПРАРОДИ'ТЕЛЬ** *м.*, **ПРАРОДИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж, книж. устар.*— ыруг башлыгы, иң борынгы әби (баба).

**ПРА'СОЛ** *м. устар.*— ит, балык, терлек белән сату итүче.

**ПРА'СОЛЬСТВО** *ср. мн.* нет, *обл. устар.*— терлек, балык, ит белән сату итү.

**ПРАХ** *м. мн.* нет, *книж.*— 1. *устар. (пыль)* тузан; 2. фани нәрсә, бетә торган нәрсә; *деньги прах, вот что я тебе говорю (А. Островский)* — акча ул фани нәрсә,— дим мин сиңа; 3. мәет (үлгән кешенең гәүдәсе яки яндырылганнан соң калган көле).◇ **Здесь покоится прах поэта**— монда шагыйрь күмелгән. **Урна с прахом** — мәет көле салынган савыт. **Прахом пойти** или **рассыпаться** *разг.*— юкка чыгу, һәлак булу. **На кой прах** *вульг.*— ни шайтаныма кирәк. **Прах его возьми** *бран.*— дөмексен, тончыксын. **Разбить в пух и прах** — тар-мар итү. **Развеять в прах** — көлен күккә очыру. **Повергнуть в прах** — юк итү. **Мир его праху** — кабередә тыныч ятсын, авыр туфрагы җиңел булсын.

**ПРА'ЧЕЧНАЯ** *ж.*— кер юу йорты.

**ПРА'ЧЕЧНИК** *м. спец.*— кер юу йортында эшләүче.

**ПРА'ЧКА** *ж.* — кер юучы (хатын-кыз).

**ПРА'ШИВАТЬ** *несов. устар.*— сораштыргалау.

**ПРАЩ** *м.*, **ПРА'ЩА** *ж. истор.*— пращ (борынгы заманда ату коралы — таш атар өчен кулланылган элмәкле каеш).

**ПРА'ЩУР** *м. книж.* — борынгы баба, ыруг башлыгы.

**ПРАЯЗЫ'К** *м. лингв.*— баба тел (тарихи-чагыштырма тел белемендә: тарихи чагыштырма метод кулланып, теоретик рәвештә күз алдына китерелгән борынгы тел).

**ПРАЯЗЫКО'ВЫЙ** *лингв.*— баба тел ...-ы; *праязыковая теория* — баба тел теориясе.

**ПРЕБОГА'ТЫЙ** *разг.*— бик бай.

**ПРЕБО'ЛЬНО** *нареч. разг.*— бик нык авырттырып; *ударить преобольно* — бик нык авырттырып сугу.

**ПРЕБЫВА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— к. пребывать.

**ПРЕБЫВА'ТЬ** *несов.*— булу, тору; *пребывать в Москве* — Москвада булу; *пребывать в неведении* — белмичә тору.

**ПРЕБЫ'ТЬ** *сов. книж. устар.*— к. пребывать.

**ПРЕВАЛИ'РОВАТЬ** *несов. книж.*— күпчелек булу, артык булу, өстен тору, өстен булу, өстенлек итү; *общенародный язык превалирует над местными диалектами* — гомумхалык теле җирле диалектлардан өстен тора.

**ПРЕВЕНТИ'ВНЫЙ** *книж.* — превентив, саклау өчен ясалган, саклык...-ы; *превентивная прививка* — саклау өчен ясалган прививка; *превентивные меры* — саклык чаралары.

**ПРЕВЗОЙТИ'** *сов.*— 1. өстен чыгу, уздыру, узып китү; *превзойти всех мужеством* — батырлык ягыннан бөтенесеннән дә өстен чыгу; *промышленность Советского Союза превзошла довоенный уровень развития во много раз* — Советлар Союзы промышленносте сугышка кадәр булган дәрәҗәдән күп тапкыр узып китте; 2. арттыру, арттырып җибәрү; *превзойти ожидания* — көтелгәннән дә арттырып җибәрү. ◇ **Превзойти (самого) себя** *книж.* — көткәннән артык эшләү (булдыру, башкару һ. б.).

**ПРЕВОЗВЫ'СИТЬ** *сов. устар.* — артык күтәреп җибәрү, кирәгеннән артык мактау.

**ПРЕВОЗВЫ'СИТЬСЯ** *сов. книж. ритор. устар.*— 1. *(стать прославленным)* даңлыклы булу, шөһрәт казану; 2. *(стать гордым)* тәкәббердәнү, тәкәбберләнеп китү, әллә кем булу.

**ПРЕВОЗВЫША'ТЬ** *несов. книж.*— к. превозвысить.

**ПРЕВОЗВЫША'ТЬСЯ** *несов. книж. ритор. устар.* — 1. к. превозвыситься; 2. *страд.* артык күтәреп җибәрелү, кирәгеннән артык мактау.

**ПРЕВОЗМОГА'ТЬ** *несов. книж. устар.*— к. превозмочь.

**ПРЕВОЗМО'ЧЬ** *сов. книж.*— җиңү, җиңеп чыгу, түзү, бирешмәү, чыдау; *превозмочь усталость* — арыганлыкка түзү, арыганлыкка бирешмәү.

**ПРЕВОЗНЕСТИ'** *сов. книж. ритор.* — к. превозносить.

**ПРЕВОЗНЕСТИ'СЬ** *сов. книж. ритор. устар.*— һаваланып китү, тәкәбберләнеп

китү, үзен-үзе әллә кемгә куя башлау, борын күтәрү.

**ПРЕВОЗНОСИ'ТЬ** *несов. книж. ритор.*— артык югары күтәрү, кирәгеннән артык мактау, күккә күтәрү.

**ПРЕВОЗНОСИ'ТЬСЯ** *несов. книж. ритор.*— 1. к. превознестись; 2. *страд.* күккә күтәрелү, кирәгеннән артык мактал у.

**ПРЕВОСХОДИ'ТЕЛЬСТВО** *ср. офиц.*— галиҗәнап (1. революциягә чаклы генерал-майор һәм генерал-лейтенант чинындагы хәрбиләргә яки 4, 3 класс чиннарына эндәшкәндә әйтелә торган титул; 2. дипломатлар теләндә чит илнең хөкүмәт җитәкчеләренә һәм членнарына эндәшкәндә хөрмәтләп әйтелә торган сүз).

**ПРЕВОСХОДИ'ТЬ** *несов. книж.*— өстен булу, күбрәк булу; *превосходить численностью* — сан ягыннан күбрәк булу.

**ПРЕВОСХО'ДНО** *разг. нареч.* — бик шәп, бик яхшы, бик әйбәт; *превосходно говорит по-французски* — французча бик яхшы сөйли.

**ПРЕВОСХО'ДНЫЙ** — бик яхшы, бик әйбәт; *превосходный человек* — бик яхшы кеше. ◇ **Превосходная степень** *грам.*— артыклык дәрәҗәсе.

**ПРЕВОСХО'ДСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.*— артыклык, өстенлек; *показать свое превосходство* — үзенең өстенлеген күрсәтү.

**ПРЕВОСХО'ДСТВОВАТЬ** *несов. книж. устар.*— өстен булу, югары тору.

**ПРЕВРАТИ'ТЬ** *сов. книж.*— әйләндерү, эверелдерү, үзгәртү; *превратить дрова в уголь* — утынны күмергә әйләндерү. ◇ **Превратить дело в шутку** — эшне уенга бору.

**ПРЕВРАТИ'ТЬСЯ** *сов.*— эверелү, әйләнү; *гранит превратился в песок* — гранит комга эверелде. ◇ **Превратиться в слух** *книж.*— йотылып тыңлау, бирелеп тыңлау.

**ПРЕВРА'ТНОСТЬ** *ж. книж.*— 1. үзгәрүчәнлек, үзгәрешлек; алмашынучанлык; *превратность счастья* — бәхетнең үзгәрүчәнлеге; 2. көтмәгәндәге үзгәреш; *превратность жизни военной ты знаешь* (*Некрасов*) — хәрби тормышның көтмәгәндәге үзгәрешләрен син беләсең.

**ПРЕВРА'ТНЫЙ** *книж.*— 1. үзгәрүчән, үзгәрешле; *превратная судьба* — үзгәрүчән язмыш; 2. ялган, үзгәртелгән, бозылган, киресенчә аңлангаи; *превратное понятие* — киресенчә аңлангаи төшенчә.

**ПРЕВРАЩА'ТЬ** *несов. книж.*— к. превратить.

**ПРЕВРАЩА'ТЬСЯ** *несов. книж.*— 1. к. превратиться; 2. *страд.* әйләндерелү, эверелдерелү.

**ПРЕВРАЩЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — к. превратить, превратиться.

**ПРЕВЫ'СИТЬ** *сов. книж.*— 1. арттыру, арттырып үтәү, арттырып җибәрү, арту; *превысить план* — планнан тыш арттырып җибәрү, планны арттырып үтәү; *расход не превысит ста рублей* — расход йөз сумнан артмас; 2. *устар.* (*превзойти, обнаружить превосходство*) өстен чыгу, өстен булу. ◇ **Превысить власть, превысить свои полномочия** — үзенә бирелгән властьны арттырып куллану, законсыз эш итү, закон бозып эш итү.

**ПРЕВЫ'СПРЕННЫЙ** *книж. ритор.* — бик кабартылган, бик күпертелгән; *превыспренный стиль* — бик күпертелгән стиль.

**ПРЕВЫША'ТЬ** *несов. книж.*— к. превысить.

**ПРЕВЫША'ТЬСЯ** *несов. книж. страд.*— 1. арттырылу, арттырып үтәлү; 2. законсыз эш ителү, законнан тыш эш ителү.

**ПРЕВЫ'ШЕ** *нареч. книж. устар.*— югарырак, бик югары, күп мәртәбә югары; *для советских людей интересы родины превыше всего* — совет кешеләре өчен ватан интереслары бар нәрсәдән дә югары. ◇ **Превыше всего** *книж.* — барыннан да югары.

**ПРЕВЫШЕ'НИЕ** *ср. книж.*— 1. к. превысить, превышать; 2. өстәмә, артык; *задание выполнено с превышением* — задание артыгы белән үтәлгән.

**ПРЕГРА'ДА** *ж. книж.*— 1. киртә; 2. *перен.* киртә, комачаулык; *преодолеть все преграды в жизни* — тормышта очраган барлык комачаулыкларны җиңеп чыгу. ◇ **Грудобрюшная преграда** — к. грудобрюшный.

**ПРЕГРАДИ'ТЬ** *сов. книж.*— 1. киртәләү, аркылы төшү; *часовой преградил ему дорогу* — часовой аның юлына аркылы төште; 2. *перен.* (*запретить или воспрепятствовать*) тыю, комачаулау.

**ПРЕГРАЖДА'ТЬ** *несов. книж.*— к. преградить.

**ПРЕГРАЖДА'ТЬСЯ** *несов. книж. страд.*— 1. киртәләнү, бүленү (юлы); 2. тыелу, юлы киселү.

**ПРЕГРАЖДЕ'НИЕ** *ср. книж.*— 1. к. преградить; 2. *устар.* к. преграда 1.

**ПРЕГРЕША'ТЬ** *несов. книж. устар.*— к. прегрешить.

**ПРЕГРЕШЕ'НИЕ** *ср. книж. устар.*— гөнаһ, ярамаган эш.

**ПРЕГРЕШИ'ТЬ** *сов. книж. устар., церк.* — хата ясау, гөнаһ эшләү.

**ПРЕД** и **ПРЕ'ДО** *предлог*—алдында, каршында, алдына, каршына; *пред нею* — аның алдында; *предо мной* — минем алдымда.

**ПРЕДАВА'ТЬ** *несов. книж.* — к. предать.

**ПРЕДАВА'ТЬСЯ** *несов. книж.*— к. предаться.

**ПРЕДА'НИЕ** *ср. книж.*— 1. (*действие*) к. предать; 2. риваять, легенда; *древнее предание* — борынгыдан килгән риваять (легенда).

**ПРЕ'ДАННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — бирелгәнлек, чын күңелдән бирелгәнлек; *преданность своему делу* — үз эшенә бирелгәнлек.

**ПРЕ'ДАННЫЙ** *книж.*— чын күңелдән бирелгән, ихлас күңелдән ышанган; *преданный своему делу* — үз эшенә чын күңелдән бирелгән. ◇ **Преданный забвению** — күптән онытылган; *преданное*

*забвению дело* — күптән онытылган эш. **Преданный друг** — ихлас дус, чын дус.

**ПРЕДА'ТЕЛЬ** *м.*, **ПРЕДА'ТЕЛЬНИЦА** *ж.* — **1.** хыянәтче, хаин, сатлык җан; **2.** *разг. шутл. (разгласитель какого-н. секрета)* кеше серен фаш итүче, хыянәтче.

**ПРЕДА'ТЕЛЬСКИЙ** — **1.** хыянәтчел, хаиннарча..., хаиннарга хас; *предательский поступок* — хыянәтчел эш; **2.** *перен.* мәкерле, явыз уйлы, ышанычсыз, шикле; *предательский смех* — мәкерле көлү; *предательская погода* — ышанычсыз һава торышы.

**ПРЕДА'ТЕЛЬСТВО** *ср.* — хыянәт, хыянәт итү, сатылу, хаинлек.

**ПРЕДА'ТЬ** *сов. книж.* — **1.** хыянәт итеп бирү; *предать врагам крепость* — хыянәт итеп крепостьны дошманга бирү; **2.** сату, хыянәт итү, тотып бирү; *предать своего друга* — үз дустыңны сату, үз дустына хыянәт итү. ◇ **Предать огню** — утка тоту, ут төртү. **Предать казни** — үлем җәзасына бирү. **Предать суду** — судка бирү. **Предать забвению** — оныту. **Предать гласности** — фаш итү. **Предать проклятию** — каргау. **Предать смерти** — үтерү. **Предать земле** — күмү, җирләү.

**ПРЕДА'ТЬСЯ** *сов.* — **1.** *устар.* бирелү; *предаться всей душой новым товарищам* — җаны-тәне белән яңа дусларга бирелү; *трус предался неприятелю* — куркак дошман кулына бирелде; **2.** чуму, бирелү, бирелеп китү, сабышу; *предаться печали* — кайгыга чуму; *предаться мечтам* — хыялга бирелү, хыялга бирелеп китү; *предаться порокам* — бозыклыкка бирелеп китү; *предаться пьянству* — эчкелеккә бирелү.

**ПРЕДБА'ННИК** *м.* — мунча алды, мунчаның алгы бүлмәсе.

**ПРЕДБУ'ДУЩИЙ** *книж. устар.* — киләчәк; *на предбудущее время* — киләчәк вакытка.

**ПРЕДВАРЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — к. предварить.

**ПРЕДВАРИ'ТЕЛЬНО** *нареч.* — алдан, баштан, алда, әүвәл, элек, башта; *надо всё предварительно хорошенько обдумать* — башта бөтенесен яхшылап уйлап карарга кирәк.

**ПРЕДВАРИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — алдан эшләнгәнлек, алдан чарасы күрелгәнлек.

**ПРЕДВАРИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — алдан, алдан эшләнгән, алдан күрелгән, алдан чарасы күреп куелган; *предварительные приготовления* — алдан эшләнгән хәзерлекләр; *предварительные меры* — алдан күрелгән чаралар; *предварительное следствие (юр.)* — алдан тикшерү; *предварительное заключение (юр.)* — алдан төрмәгә ябып кую, алдан кулга алу (суд карарына чаклы); *предварительное соглашение* — алдан килешү, алдан вәгъдәләшү; *предварительные переговоры* — алдан сөйләшүләр.

**ПРЕДВАРИ'ТЬ** *сов. книж. устар.* — **1.** *(предупредить, уведомить заранее)* алдан белдереп кую, алдан хәбәр итү; **2.** алдан чара күреп кую, алдан эшләп кую; *предварить события* — вакыйгалардан алда чара күреп кую.

**ПРЕДВАРЯ'ТЬ** *несов. книж. устар.* — к. предварить.

**ПРЕДВАРЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. книж. устар.* — алдан белдерелеп куелу, алдан чара күреп куелу.

**ПРЕДВЕ'СТИЕ** *ср. книж.* — билге, галәмәт, хәбәр; *предвестие бури* — давыл галәмәте; *предвестие осени* — көз билгесе.

**ПРЕДВЕ'СТНИК** *м.*, **ПРЕДВЕ'СТНИЦА** *ж. книж.* — алдан хәбәр бирүче; билге; галәмәт.

**ПРЕДВЕЩА'НИЕ** *ср. книж. устар.* — к. предвестие.

**ПРЕДВЕЩА'ТЬ** *несов. книж.* — **1.** *устар. (предрекать)* алдан әйтү, алдан хәбәр бирү, алдан белдерү; **2.** билге булып тору, күрсәтеп тору, алдан ук белдереп тору; *тучи предвещали ненастье* — болытлар алдан ук көн бозылуны белдереп торалар иде.

**ПРЕДВЕЩА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж. устар.* — алдан әйтелү, алдан белдерелү, алдан хәбәр бирелү.

**ПРЕДВЗЯ'ТОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — алдан ук дөрес түгеллек, башта ук ялгышлык; *предвзятость мысли* — фикернең алдан ук дөрес түгеллеге.

**ПРЕДВЗЯ'ТЫЙ** *книж.* — башта ук ялгыш булган; *он пришёл с предвзятым мнением* — ул алдан ук ялгыш булган фикер белән килгән; *предвзято судить о чем-н.* — берәр нәрсә турында алдан ук ялгыш фикер йөртү.

**ПРЕДВИ'ДЕНИЕ** *ср. книж.* — алдан күрү, алдан күрә белү (берәр нәрсәнең ничек булачагын алдан белеп тору); *предвидение дальнейших событий* — булачак вакыйгаларны алдан күрә белү; *научное предвидение* — фәнни алдан күрү (фәнни мәгълүматларга нигезләнеп берәр нәрсәнең ничек булачагын алдан күрү).

**ПРЕДВИ'ДЕТЬ** *несов. книж.* — алдан күрү, алдан сизү, алдан күреп тору; *предвидеть ход событий* — вакыйгаларның барышын алдан күрү.

**ПРЕДВИ'ДЕТЬСЯ** *несов. книж.* — алдан күренеп тору, алдан беленеп тору, алдан мәгълүм булу, көтелү; *никаких изменений не предвидится* — бернинди үзгәрешләр дә көтелми.

**ПРЕДВКУСИ'ТЬ** *сов. книж.* — к. предвкушать.

**ПРЕДВКУША'ТЬ** *несов. книж.* — татлы хыялга бату, булачак берәр нәрсәне уйлап алдан ләззәтләнү, алдан ук зәвыклану; *предвкушать победу* — булачак җиңүне уйлап алдан ук ләззәтләнү.

**ПРЕДВКУШЕ'НИЕ** *ср. книж.* — к. предвкушать.

**ПРЕДВОДИ'ТЕЛЬ** *м. книж.* — предводитель, башлык; *предводитель племени* — кабилә башлыгы. ◇ **Предводитель дворянства** *дореvол.* — дворяннар предводителе (дворяннарның сайлап куелган житәкчесе).

**ПРЕДВОДИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж. книж.* — к. предводитель.

**ПРЕДВОДИ'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет — башлык булу, житәкчелек.

**ПРЕДВОДИ'ТЕЛЬСТВОВАТЬ** *несов. книж.*— житәкчелек итү, башлык булу.

**ПРЕДВОДИ'ТЕЛЬША** *ж. разг. дорев ол.*— дворяннар предводителенең хатыны.

**ПРЕДВОЕ'ННЫЙ** — сугышка кадәр булган, сугыш алдыннан булган; *предвоенные события* — сугыш алдыннан булган вакыйгалар.

**ПРЕДВОЗВЕ'СТИЕ** *ср. книж. устар.*— к. предвозвестить.

**ПРЕДВОЗВЕСТИ'ТЬ** *сов. книж.*— алдан әйтеп кую, алдан белдереп кую.

**ПРЕДВОЗВЕ'СТНИК** *м. книж. ритор.*— к. предвестник.

**ПРЕДВОЗВЕЩА'ТЬ** *несов. книж.*— к. предвозвестить.

**ПРЕДВОЗВЕЩА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.*— алдан әйтеп куелу, алдан белдереп куелу.

**ПРЕДВОСХИ'ТИТЬ** *сов. книж.* — алдан белеп алу; алдан уйлап табу, алдан эшләп кую, алдан сизү; *предвосхитить события* — вакыйгаларны алдан белеп алу.

**ПРЕДВОСХИЩА'ТЬ** *несов. книж.*— к. предвосхитить.

**ПРЕДВОСХИЩЕ'НИЕ** *ср. книж.*— к. предвосхитить.

**ПРЕДВЫ'БОРНЫЙ** *полит.* — сайлау алды...-ы; *предвыборная кампания* — сайлау алды кампаниясе.

**ПРЕДГО'РНЫЙ** *книж.*— тау янындагы; *предгорная местность* — тау янындагы жир, тау асты, тау итәге.

**ПРЕДГО'РЬЕ** *ср. книж.*— тау итәге, тау яны, тау асты.

**ПРЕДГРО'ЗЬЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— 1. яшенле яңгыр алды; 2. *перен.* катастрофа алды, куркыныч вакыйгалар алдыннан булган вакыт.

**ПРЕДДВЕ'РИЕ** *ср. книж.*— 1. ишек төбе, ишек яны; 2. *перен.* беренче дәвер, башлангыч чор; *в преддверии науки* — фәннең башлангыч дәверендә. ◇ **В преддверии театрального сезона** — театр сезоны ачылыр алдыннан.

**ПРЕДЕ'Л** *м. книж.*— 1. чик; *за пределами города* — шәһәр чигеннән тышта, шәһәр тышында; 2. эч; *в пределах страны* — ил эчендә; *в пределах года* — ел эчендә; 3. *поэт. устар.* ил; *покинул родной предел* — туган илен ташлап китте; 4. *перен.* иң югары дәрәҗә, чик; *нет предела желаниям* — теләкләрнең чиге юк; *всему есть предел* — һәрнәрсәнең чиге бар; *положить предел* — чик кую; *находиться на пределе* — актык чиктә булу; *предел совершенства* — камиллекнең иң югары дәрәҗәсе; *перейти пределы дозволенного* — рөхсәт ителгәннән чигенә чыгу.

**ПРЕДЕ'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— ахыр чик.

**ПРЕДЕ'ЛЬНЫЙ** *книж.*— ахыр чиктәге, актыккы, иң соңгы, соңгы дәрәҗәдәге; *предельный срок* — иң соңгы срок.

**ПРЕДЕ'ЛЬЧЕСТВО** *ср. мн.* нет — пределчылык (артка калган эш нормалары белән чикләнеп, производство мөмкинлекләрен үстерүгә киртә булып тора торган эш практикасы).

**ПРЕДЕ'ЛЬЩИК** *м.*— пределчы (артка калган нормалардан чыгып эш итүче).

**ПРЕДЕРЖА'ЩИЙ** *офиц. устар.*: **власть предержащая** — югары власть; **власти предержащие** — власть бирелгән кешеләр, власть башында торучылар.

**ПРЕДЗАКА'ТНЫЙ** *книж.*— кояш бату алдындагы; *предзакатный час* — кояш бату алдындагы вакыт.

**ПРЕДЗИ'МЬЕ** *ср. мн.* нет — кыш алды.

**ПРЕДЗНАМЕНОВА'НИЕ** *ср. книж.*— билге, галәмәт; *хорошее предзнаменование* — яхшы билге.

**ПРЕДЗНАМЕНОВА'ТЬ** *несов. книж. устар.*— билге булу, галәмәт булу, алдан белдереп тору.

**ПРЕДИКА'Т** *м. спец.*— 1. предикат (логикада: фикер йөртүнең предметын — субъектны билгели торган төшенчә); 2. *грам.* предикат, хәбәр.

**ПРЕДИКАТИ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *филос. грам.* — предикативлык, хәбәрлек.

**ПРЕДИКАТИ'ВНЫЙ** *филос. грам.*— предикатив, хәбәрлекле; *предикативная связь* — предикатив бәйләнеш.

**ПРЕДИКА'ЦИЯ** *ж.*— предикация (1. *филос.* субъектның эчтәлеген предикат белән ачып бирү; 2. *грам.* җөмлә кисәкләре арасында предикатив бәйләнеш барлыгын билгеләү).

**ПРЕДИСЛО'ВИЕ** *ср.*— кереш сүз, сүз башы.

**ПРЕДЛАГА'ТЬ** *несов.*— к. предложить.

**ПРЕДЛАГА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— тәкъдим ителү.

**ПРЕДЛЕЖА'ТЬ** *несов. книж. устар.*— алда тору; күз алдында яту, *предлежащее дело* — күз алдында торган эш.

**ПРЕДЛО'Г** I *м.*— сылтау, сәбәп; *под предлогом болезни* — авыру сылтавы белән.

**ПРЕДЛО'Г** II *м. грам.*— бәйлек.

**ПРЕДЛОЖЕ'НИЕ** I *ср* — 1. *(действие)* к. предложить; 2. тәкъдим; *внести конкретное предложение* — конкрет тәкъдим кертү; 3. *офиц. устар.* тәкъдим ясау (өйләнешү турында); 4. *только ед. экон.* тәкъдим (базарга товар чыгару); *закон спроса и предложения* — сорау һәм тәкъдим законы.

**ПРЕДЛОЖЕ'НИЕ** II *ср. грам.*— җөмлә; *сложное предложение* — кушма җөмлә; *придаточное предложение*— иярчен җөмлә.

**ПРЕДЛОЖИ'ТЬ** *сов.*— 1. тәкъдим итү; *предложить кандидатуру* — кандидатура тәкъдим итү; 2. таләп итү, кушу; *предложить закончить работу в срок* — эшне срогына бетерүне таләп итү; *ему предложили подать рапорт* — аңа рапорт бирергә куштылар. ◇ **Предложить руку и сердце** *перен. офиц. устар.* — кияүгә чыгарга тәкъдим итү, тәкъдим ясау. **Предложить вопрос** — сорау бирү.

**ПРЕДЛО'ЖНЫЙ** I *грам.* — предлоглы, бәйлекле; *предложная конструкция* — предлоглы конструкция.

**ПРЕДЛО'ЖНЫЙ** II: **предложный падеж** *грам.* — предложный падеж.

**ПРЕДМЕ'СТНИК** *м.*, **ПРЕДМЕ'СТНИЦА** *ж. книж. устар.* — (берәр урында) элек эшләгән кеше.

**ПРЕДМЕ'СТЬЕ** *ср. книж.* — бистә, шәһәр янындагы җир.

**ПРЕДМЕ'Т** *м.* — 1. әйбер, предмет; *предметы окружающего мира* — әйләнә-тирәдәге әйберләр, тирә-яктагы предметлар; 2. әйбер, кирәк-ярак; *предметы широкого потребления* — киң куллану әйберләре; *предметы домашнего обихода* — йорт кирәк-яраклары; 3. предмет, тема; *предмет научного исследования* — гыйльми тикшерену темасы; *предмет изучения* — өйрәнелә торган предмет; *учебные предметы* — укыту предметлары, уку фәннәре. ◇ **Предмет любви** — яраткан нәрсә. **Предмет увлечения** — мавыккан нәрсә. **На предмет** — өчен; *на предмет получения пособия* — пособие алу өчен. **На сей предмет** — бу турыда, бу очракта, моның турында; *на сей предмет он уж позаботился* — моның турында ул үзе хәстәрен күрде инде. **Предмет спора** — бәхәс тудырган нәрсә. **На тот предмет, если** *канц.* — башка берәр нәрсә булса, булып калса, фәләнчә булган очракта.

**ПРЕДМЕ'ТНИК** *м.*, **ПРЕДМЕ'ТНИЦА** *ж. учит. арго* — предметник, аерым фән укытучысы (мәсәлән, география укытучысы).

**ПРЕДМЕ'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *науч.* — предметлык; предметлылык; *предметность искусства* — сәнгатьнең предметлылыгы; *категория предметности в языке* — телдә предметлык категориясе.

**ПРЕДМЕ'ТНЫЙ** *книж.* — әйберлек...-ы; *предметный смысл* — әйберлек мәгънәсе. ◇ **Предметный указатель** — темалар күрсәткече. **Предметная система преподавания** — фәннәрне аерым укыту системасы, предметлап укыту системасы.

**ПРЕДМО'СТНЫЙ** *спец.* — күпер алдындагы; *предмостное укрепление* — күпер алдындагы ныгытма.

**ПРЕДМО'СТЬЕ** *ср. спец.* — күпер алды, күпергә керү урыны.

**ПРЕДНАЗНАЧА'ТЬ** *несов. книж.* — к. предназначить.

**ПРЕДНАЗНАЧА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — алдан билгеләнү, алдан билгеләп куелу.

**ПРЕДНАЗНАЧЕ'НИЕ** *ср. книж.* — 1. *только ед.* к. предназначить; 2. *устар.* язмыш, тәкъдир, күрәчәк; *верить в своё предназначение* — үзеңнең язмышыңа ышану.

**ПРЕДНАЗНА'ЧИТЬ** *сов. книж.* — алдан билгеләү, алдан билгеләп кую.

**ПРЕДНАМЕ'РЕННО** *нареч.* — алдан ук хәзерләнеп, алдан ук уйлап.

**ПРЕДНАМЕ'РЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет. *книж.* — алдан уйлангалык (гадәттә: усал нияләт, усал уй); *в его поступке не было преднамеренности* — аның эшендә усал ният юк иде.

**ПРЕДНАМЕ'РЕННЫЙ** *книж.* — алдан ук уйлап эшләнгән (гадәттә усал ният белән); *преднамеренное действие* — алдан ук уйлап эшләнгән эш.

**ПРЕДНАЧЕРТА'НИЕ** *ср. книж. ритор. устар.* — алдан ук бирелгән боерык, алдан ук ясалган күрсәтмә.

**ПРЕДНАЧЕРТА'ТЬ** *сов. книж. ритор. устар.* — алдан билгеләү, алдан билгеләп кую, алдан юл сызып кую, юл күрсәтеп кую.

**ПРЕДО'** *предлог* — к. пред.

**ПРЕДОБЕ'ДЕННЫЙ** — төшке аш алды...-ы; *предобеденное время* — төшке аш алды вакыты.

**ПРЕДО'БРЫЙ** *разг. фам.* — бик яхшы, бик йомшак күңелле; *предобрый человек* — бик яхшы кеше.

**ПРЕ'ДОК** *м. книж.* — 1. борынгы баба, ыруг башлыгы; 2. *только мн. перен.* ата-бабалар; *наши предки* — безнең ата-бабаларыбыз.

**ПРЕДОКТЯ'БРЬСКИЙ** — Октябрь алды...-ы; Октябрь бәйрәме алды...-ы; *предоктябрьское социалистическое соревнование* — Октябрь бәйрәме алды социалистик ярышы.

**ПРЕДО'ЛГИЙ** *разг.* — бик озак; *предолгий разговор* — бик озак сөйләшү.

**ПРЕДОПРЕДЕЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — 1. *(действие)* к. предопределить; 2. *церк. устар. (судьба)* язмыш, тәкъдир.

**ПРЕДОПРЕДЕЛИ'ТЬ** *сов. книж.* — алдан билгеләү, алдан билгеләп кую; *успех предопределил его дальнейшую судьбу* — уңыш аның киләчәктәге язмышын алдан билгеләп куйды.

**ПРЕДОПРЕДЕЛИ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — алдан билгеләнү, алдан билгеләнеп куелу.

**ПРЕДОПРЕДЕЛЯ'ТЬ** *несов. книж.* — к. предопределить.

**ПРЕДОПРЕДЕЛЯ'ТЬСЯ** *несов. книж.* — к. предопределиться.

**ПРЕДОРОГО'Й** *разг. фам.* — артык кыйбат, чиктән тыш кыйбат.

**ПРЕДОСТА'ВИТЬ** *сов. книж.* — 1. бирү; *предоставить место* — урын бирү; 2. ирек бирү, мөмкинлек бирү, үз ихтыярына кую; *предоставьте ему самому решать этот вопрос* — бу мәсьәләне хәл итүне аның үз ихтыярына куегыз. ◇ **Предоставить самому себе** — үз иркенә кую.

**ПРЕДОСТАВЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — к. предоставить, предоставлять.

**ПРЕДОСТАВЛЯ'ТЬ** *несов. книж.* — к. предоставить.

**ПРЕДОСТАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — бирелү, мөмкинлек бирелү, ихтыярына куелу, ирек бирелү; *женщине в СССР предоставляются равные права с мужчиной* — СССРда хатын-кызларга ирләр белән бертигез хокук бирелә.

**ПРЕДОСТЕРЕГА'ТЬ** *несов. книж.* — к. предостеречь.

**ПРЕДОСТЕРЕГА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — алдан кисәтелү, сак булырга кушылу, сакланырга кушылу.

**ПРЕДОСТЕРЕЖЕ'НИЕ** *ср. книж.* — 1. к. предостеречь; 2. *право* каты кисәтү (суд тарафыннан акланса да куркынычлы исәп-

ләнгән кешене, судтан соң да җинаять эшләмәсен өчен, алдан каты кисәтеп кую).

**ПРЕДОСТЕРЕ'ЧЬ** *сов. книж.*— алдан кисәтү, сак булырга кушу, сакланырга кушу.

**ПРЕДОСТОРО'ЖНОСТЬ** *ж. книж.*— саклык, сак булучылык; *меры предосторожности* — саклык чаралары.

**ПРЕДОСУДИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— гаеп итәрлек булу, гаепкә алырлык булу.

**ПРЕДОСУДИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.*— гаепкә алырлык, гаеп итәрлек; *предосудительный поступок* — гаеп итәрлек эш.

**ПРЕДОТВРАТИ'ТЬ** *сов. книж.*— булдырмый калу, саклап калу (алдан чарасын күреп).

**ПРЕДОТВРАЩА'ТЬ** *несов. книж.*— к. предотвратить.

**ПРЕДОТВРАЩА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.*— саклап калыну, булдырмый калдырылу (алдан чарасын күреп).

**ПРЕДОТВРАЩЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— к. предотвратить.

**ПРЕДОХРАНЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— к. предохранить.

**ПРЕДОХРАНИ'ТЕЛЬ** *м. тех.*— саклагыч, предохранитель.

**ПРЕДОХРАНИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж. спец.*— саклагыч, саклык...-ы; саклый торган; *предохранительные меры* — саклык чаралары.

**ПРЕДОХРАНИ'ТЬ** *сов. книж.*— саклау, саклап алып калу; *предохранить от заразных болезней* — йогышлы авырулардан саклап алып калу.

**ПРЕДОХРАНЯ'ТЬ** *несов. книж.*— к. предохранить.

**ПРЕДОХРАНЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.*— саклану, саклап алып калыну.

**ПРЕДОЩУТИ'ТЬ** *сов. книж. устар.*— алдан сизү, алдан сизеп алу.

**ПРЕДОЩУЩА'ТЬ** *несов. книж. устар.*— к. предощутить.

**ПРЕДОЩУЩА'ТЬСЯ** *несов. книж. устар.*— алдан сизелү, сизелеп алыну.

**ПРЕДОЩУЩЕ'НИЕ** *ср. книж. устар.*— к. предощутить.

**ПРЕДПАРЛА'МЕНТ** *м. полит.*— предпарламент (1917 елны Вакытлы хөкүмәт каршында эре буржуазия, меньшевиклар һәм эсерлар тарафыннан төзелгән, киңәш бирү хокукы булган вакытлы совет).

**ПРЕДПИСА'НИЕ** *ср. книж. офиц.*— 1. *офиц.* язма боерык; 2. боерык, приказ; *секретное предписание* — яшерен приказ; 3. киңәш, кушкан нәрсәләр; *выполнить предписание врача* — врачның киңәшен җиренә җиткерү, врачның кушканнарын үтәү.

**ПРЕДПИСА'ТЬ** *сов. книж.*— 1. *офиц.* *(приказать)* боерык бирү, кушу, боеру; 2. билгеләү; *предписать диету* — диета билгеләү.

**ПРЕДПИ'СЫВАТЬ** *несов. книж.*— к. предписать.

**ПРЕДПИ'СЫВАТЬСЯ** *несов. книж.*— боерык бирелү, кушылу, билгеләнү.

**ПРЕДПЛЕЧЕВО'Й** *анат.*— беләк сөягендәге; *предплечевой сустав* — беләк сөягендәге буын.

**ПРЕДПЛЕ'ЧЬЕ** *ср. анат.*— беләк сөяге (терсәктән беләзеккә хәтле).

**ПРЕДПЛЮСНА'** *ж. анат.*— тубык сөяге.

**ПРЕДПОЛАГА'ЕМЫЙ** — уйланылган, фараз ителгән.

**ПРЕДПОЛАГА'ТЬ** *несов.*— 1. к. предположить; 2. ният итү, уйлау; *я предполагаю выехать завтра утром* — мин иртәгә иртән китәргә уйлыйм; 3. таләп итү, сорау, шарт кую; *успешный исход дела предполагает предварительную подготовку* — эшнең уңышлы барып чыгуы алдан хәзерләнүне таләп итә.

**ПРЕДПОЛАГА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— фараз ителү, чамалану, уйлану.

**ПРЕДПОЛОЖЕ'НИЕ** *ср.*— к. предположить.

**ПРЕДПОЛОЖИ'ТЕЛЬНО** *нареч. книж.*— чамалап, чама белән; *назначить предположительно день отъезда* — китәсе көнне чамалап билгеләү.

**ПРЕДПОЛОЖИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. книж.*— фараз ителгәнлек, чамаланганлык.

**ПРЕДПОЛОЖИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — чамаланган, уйланылган, фараз ителгән; *предположительный результат* — фараз ителгән нәтиҗә.

**ПРЕДПОЛОЖИ'ТЬ** *сов.*— фараз итү, чамалау, уйлау.

**ПРЕДПОЛЯ'РНЫЙ** *геогр.*— поляр түгәрәге алдындагы, поляр түгәрәге янындагы.

**ПРЕДПОСЛА'ТЬ** *сов. книж.*— кереш рәвешендә әйтеп китү (ясап китү); *предпослать докладу несколько замечаний* — доклад алдыннан кереш рәвешендә берничә искәрмә ясап китү.

**ПРЕДПОСЛЕ'ДНИЙ** — иң соңгыдан алдыгы.

**ПРЕДПОСЫЛА'ТЬ** *несов. книж.*— к. предпослать.

**ПРЕДПОСЫЛА'ТЬСЯ** *несов. книж.*— кереш рәвешендә әйтелү.

**ПРЕДПОСЫ'ЛКА** *ж. книж.*— шарт, алгы шарт; *создать нужные предпосылки* — кирәкле алгы шартлар булдыру.

**ПРЕДПОЧЕ'СТЬ** *сов.* — артыграк күрү, яхшырак дип тану, яхшырак дип исәпләү, яхшырак күрү; *предпочёл остаться дома* — өйдә калуны яхшырак күрде.

**ПРЕДПОЧИТА'ТЬ** *несов.* — к. предпочесть.

**ПРЕДПОЧИТА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— артыграк күрелү, яхшырак күрелү.

**ПРЕДПОЧТЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— 1. к. предпочесть; 2. *(уважение)* ихтирам, хөрмәт, башкаларга караганда зуррак хөрмәт.

**ПРЕДПОЧТИ'ТЕЛЬНО** *нареч. книж.*— яхшырак, артыграк; *нужно сделать об этом доклад, предпочтительно в письменной форме* — бу турыда доклад ясарга кирәк, докладның язма формада булуы яхшырак.

**ПРЕДПОЧТИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. книж.*— артыграк булу, яхшырак булу.

**ПРЕДПОЧТИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.*— иң яхшы, иң кулай, иң уңайлы; *предпочтительный исход дела* — эшнең иң уңайлы бетүе.

**ПРЕДПРА'ЗДНИЧНЫЙ**—бәйрәм алды...-ы; *предпраздничный день* — бәйрәм алды көне.

**ПРЕДПРИИ'МЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— булдыклылык, эшлеклелек; *обнаружить предприимчивость*— булдыклылык күрсәтү.

**ПРЕДПРИИ'МЧИВЫЙ** *книж.*— эшлекле, булдыклы; *предприимчивый человек* — эшлекле кеше.

**ПРЕДПРИНИМА'ТЕЛЬ** *м.* — предприниматель (предприятие тотучы капиталист).

**ПРЕДПРИНИМА'ТЕЛЬСКИЙ** — предпринимательләр...-ы, предпринимательлек...-ы, предприниматель...-ы; *предпринимательский доход* — предприниматель доходы.

**ПРЕДПРИНИМА'ТЬ** *несов. книж.*— к. предпринять.

**ПРЕДПРИНИМА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.*— күрелү; *предпринимаются меры к изданию книги* — китапны бастыру чаралары күрелә.

**ПРЕДПРИНЯ'ТЬ** *сов.*— тотыну, керешү, башлау; *предпринять научное исследование* — фәнни тикшеренүгә керешү. ◇ **Предпринять путешествие** — сәяхәткә чыгу. **Предпринять необходимые меры** — кирәкле чараларын күрү.

**ПРЕДПРИЯ'ТИЕ** *ср.*— 1. *книж.* (*предпринятое дело*) тотынган эш, керешкән эш, эш; 2. *экон.* предприятие; *мелкое предприятие* — вак предприятие.

**ПРЕДПУСКОВО'Й** *спец.*— ходка җибәрү алды...-ы, ходка җибәрү алдындагы; *предпусковые работы на метро* — метроны ходка җибәрү алдындагы эшләр.

**ПРЕДРАСПОЛАГА'ТЬ** *несов. книж.*— 1. к. предрасположить; 2. *перен.* ... китерү, ...-сы килү, теләк тудыру; *дождь предрасполагает ко сну* — яңгыр йокы китерә, яңгыр вакытында йоклыйсы килә.

**ПРЕДРАСПОЛОЖЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— сәләтлелек, бирелүчәнлек; *предрасположение к болезни* — авыруга бирелүчәнлек; *предрасположение к музыке* — музыкага сәләтлелек.

**ПРЕДРАСПОЛО'ЖЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — к. предрасположение.

**ПРЕДРАСПОЛО'ЖЕННЫЙ** — бирелүчән; *человек, предрасположенный к болезням* — авыруларга бирелүчән кеше.

**ПРЕДРАСПОЛОЖИ'ТЬ** *сов.* — хәзерләп кую, аудару; *предрасположить в свою пользу* — үз ягына аудару.

**ПРЕДРАССВЕ'ТНЫЙ** — таң алды...-ы; *предрассветный ветерок* — таң алды җиле.

**ПРЕДРАССУ'ДОК** *м.*— хорафат, юк-барга ышану. ◇ **Человек без предрассудков** *ирон. перен.*— намуссыз кеше.

**ПРЕДРАССУЖДЕ'НИЕ** *ср. книж. устар.*— к. предрассудок.

**ПРЕДРЕКА'ТЬ** *несов. книж. устар.*— к. предсказать.

**ПРЕДРЕКА'ТЬСЯ** *несов. книж. устар.*— алдан әйтеп куелу.

**ПРЕДРЕ'ЧЬ** *сов. книж. устар.*— к. предсказать.

**ПРЕДРЕША'ТЬ** *несов. книж.*— к. предрешить.

**ПРЕДРЕША'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.*— алдан хәл ителү, алдан хәл итеп куелу.

**ПРЕДРЕШИ'ТЬ** *сов.*— алдан хәл итү, алдан хәл итеп кую; *предрешить вопрос* — мәсьәләне алдан хәл итү.

**ПРЕДСЕДА'ТЕЛЬ** *м.*, **ПРЕДСЕДА'ТЕЛЬНИЦА** *ж. разг.*— председатель, рәис.

**ПРЕДСЕДА'ТЕЛЬСКИЙ** — председатель...-ы, рәис...-ы; *председательское место* — председатель урыны.

**ПРЕДСЕДА'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет, *книж. офиц.*—председательлек, рәислек.

**ПРЕДСЕДА'ТЕЛЬСТВОВАТЬ** *несов.* — председательлек итү, председатель булып эшләү.

**ПРЕДСЕ'РДИЕ** *ср. анат.* — колакчык, йөрәк алды.

**ПРЕДСКАЗА'НИЕ** *ср.*— 1. *только. ед.* (*действие*) к. предсказать; 2. алдан әйтеп куелган хәбәр, алдан әйтеп куелган сүзләр, гаиптән хәбәр бирү.

**ПРЕДСКАЗА'ТЕЛЬ** *м.*, **ПРЕДСКАЗА'ТЕЛЬНИЦА** *ж.*— алдан әйтүче, гаиптән хәбәр бирүче.

**ПРЕДСКАЗА'ТЬ** *сов.*— алдан әйтү, алдан әйтеп кую; *предсказать погоду* — һаваның нинди булачагын алдан әйтеп кую.

**ПРЕДСКА'ЗЫВАТЬ** *несов.* — к. предсказать.

**ПРЕДСКА'ЗЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — алдан әйтелү, алдан әйтеп куелу.

**ПРЕДСМЕ'РТНЫЙ** *книж.*— үлем алдындагы, үлем алды...-ы; *предсмертный час* — үлем алды сәгате.

**ПРЕДСТАВА'ТЬ** *несов. книж.*— к. предстать.

**ПРЕДСТАВИ'ТЕЛЬ** *м.*, **ПРЕДСТАВИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж.*— 1. вәкил; *представитель трудящихся* — хезмәт ияләре вәкиле; *полномочный представитель* — тулы хокуклы вәкил; 2. берсе; *корова — представитель парнокопытных* — сыер — куштояклы хайваннарның берсе.

**ПРЕДСТАВИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — күренеклелек, мәһабәтлек, күркәмлек.

**ПРЕДСТАВИ'ТЕЛЬНЫЙ** —1. *полит., право* вәкилләр...-ы; *представительное собрание* — вәкилләр җыелышы; 2. вәкилләр тарафыннан идарә итү...-ы; *представительная система* — вәкилләр тарафыннан идарә итү системасы; 3. *разг.* мәһабәт, күренекле; *представительный старик* — мәһабәт карт.

**ПРИКОЛДОВА'ТЬ** *сов. обл. нар.-поэт.*— к. приворожить.

**ПРИКОЛДО'ВЫВАТЬ** *несов. обл. нар.-поэт.*— к. привораживать.

**ПРИКОЛДО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд. обл. нар.-поэт.*— к. привораживаться.

**ПРИКОЛЕСИ'ТЬ** *сов. простореч. фам.*— (ерак җирдән яки көч-хәл белән) килү, килеп җитү.

**ПРИКО'ЛКА** *ж. разг.*— 1. *только ед. (действие)* к. приколоть 1; 2. *простореч.* брошка.

**ПРИКОЛОТИ'ТЬ** *сов.*— кадаклау, кадаклап кую.

**ПРИКОЛО'ТЬ** *сов.*— 1. кадау, кадап кую; *приколоть бант* — бант кадау; 2. *(умертвить)* чәнчеп үтерү.

**ПРИКОЛО'ТЬСЯ** *сов. разг.*— кадалу, кадап куелу.

**ПРИКОЛЬНУ'ТЬ** *сов. разг.*— (сизелерсизелмәс кенә) чәнчеп алу.

**ПРИКОМАНДИРОВА'ТЬ** *сов.*— вакытлыча җибәрү, вакытлыча билгеләү, (билгеле вакытка) командировать итү.

**ПРИКО'НЧИТЬ** *сов. разг.*— 1. *простореч.* бетерү; *всю миску щей прикончили* — бер миски щины ашап бетергәннәр; 2. *простореч.* бетерү, туктату; *прикончим эти разговоры* — бу сүзләрне бетерик (туктатыйк); 3. *перен. разг. (умертвить)* юк итү, үтерү, үтереп ташлау.

**ПРИКО'НЧИТЬСЯ** *сов. разг.*— бетү; тукталу; *разговор прикончился* — сүз бетте (тукталды).

**ПРИКОПИ'ТЬ** *сов. разг.*— (аз-азлап)җыю, (аз-азлап) туплау.

**ПРИКО'РМ** *м.* — к. прикормка.

**ПРИКОРМИ'ТЬ** *сов.*— 1. *спец.* ашатып үзенә ияләштерү; *прикормить лошадь* — атны ашатып үзенә ияләштерү; 2. *перен. разг. (подкупить)* сыйлап үз ягына аудару, сатып алу.

**ПРИКО'РМКА** *ж.*— 1. *только ед. (дей-*

*ствие)* к. прикормить; 2. азык, жим (иялэштерү өчен бирелә торган азык).

**ПРИКОРНУ'ТЬ** *сов. разг. фам.*— сөялеп яту, бөгәрләнеп яту, бөгәрләнеп ятып йокыга киту.

**ПРИКОСНОВЕ'НИЕ** *ср.*— 1. *(действие)* к. прикоснуться; 2. *только. ед. книж.* мөнәсәбәт, бәйләнеш; *к этому делу не имею никакого прикосновения* — бу эшкә минем һичнинди бәйләнешем юк.

**ПРИКОСНОВЕ'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж. офиц.*— мөнәсәбәт, бәйләнеш, катнаш.

**ПРИКОСНОВЕ'ННЫЙ** *книж. офиц.*— бәйләнеше булган, мөнәсәбәте булган, катнашкан, катнашы булган; *привлечь всех прикосновенных к делу людей* — эшкә катнашы булган барлык кешеләрне җавапка тарту.

**ПРИКОСНУ'ТЬСЯ** *сов.*— тию, тиеп киту, орыну, орынып киту; кагылу, кагылып киту.

**ПРИКОЧЕВА'ТЬ** *сов.*— күченеп килү (күчмә халыклар турында).

**ПРИКРА'ИВАТЬ** *несов.*— к. прикроить.

**ПРИКРА'ИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— кисеп иплэнү, кисеп туры китерелү, кисеп рәтләнү (киемнең аерым кисәкләре турында).

**ПРИКРА'СА** *ж. чаще мн. разг.*— арттыру, матурлау, бизәү; *он не мог говорить без прикрас* — ул арттырмыйча сөйли алмый иде.

**ПРИКРА'СИТЬ** *сов.*— арттырып сөйләү, күпертеп сөйләү; *любил прикрасить свой рассказ* — ул сөйләгәндә арттырып сөйләргә ярата иде.

**ПРИКРА'ШИВАТЬ** *несов* —к. прикрасить.

**ПРИКРА'ШИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— арттырып сөйләнү, күпертеп сөйләнү.

**ПРИКРЕПИ'ТЕЛЬНЫЙ** — беркетү...-ы, теркәү...-ы; теркәлү...-ы; *прикрепительный талон* — беркетү талоны.

**ПРИКРЕПИ'ТЬ** *сов.*— теркәү, беркетү, беркетеп кую.

**ПРИКРЕПИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. *(крепко приделаться)* берегү; 2. *разг. (стать на учёт)* учётка басу; теркәлү.

**ПРИКРЕПЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. прикрепить.

**ПРИКРЕПЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. прикрепиться; 2. *страд.* беркетелү, теркәлү.

**ПРИКРИ'КИВАТЬ** *несов.*— кычкырып-кычкырып кую (берәр кешене куркыту яки мәҗбүр итү өчен).

**ПРИКРИ'КНУТЬ** *сов.*— кычкыру, кычкырып кую.

**ПРИКРОИ'ТЬ** *сов.*— кисеп ипләү, кисеп туры китерү, кисеп рәтләү (киемнең аерым кисәкләре турында).

**ПРИКРУТИ'ТЬ** *сов.*— 1. боргычлап кую, боргычлап бәйләп кую, каерып бәйләү; 2. батыра төшү, баса төшү, бераз төшерү; *прикрутить фитиль в лампе* — лампаның филтәсен баса төшү.

**ПРИКРУ'ЧИВАТЬ** *несов.*— к. прикрутить.

**ПРИКРУ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. боргычлап бәйләп куелу; каерып бәйләнелү; 2. бераз төшерелү.

**ПРИКРЫВА'ТЬ** *несов.*— к. прикрыть.

**ПРИКРЫВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. каплану, ябылу, саклану; 2. *перен.* каплану, каплап калдырылу, яшерелү.

**ПРИКРЫ'ТИЕ** *ср.*— 1. (нәрсәдән булса да) каплый торган, саклый торган әйбер; *это дерево — плохое прикрытие от дождя* — бу агач яңгырдан начар саклый (бу агач яңгырдан саклый алмый); 2. *воен.* прикрытие (берәр нәрсәне саклау өчен булган хәрби отряд); *артиллерийское прикрытие состояло из полуроты пехоты* — артиллериянең прикрытиесе ярты рота пехотадан гыйбарәт иде. ◇ **Под прикрытием громких фраз** — күперенке фразаларга яшеренеп.

**ПРИКРЫ'ТЬ** *сов.*— 1. ябу, яба төшү, кыса төшү; *прикрыть дверь* — ишекне ябу; 2. каплау, саклау; *снег прикрыл пенья* — кар агач төпләрен каплаган; 3. *воен.* каплау; *прикрыть левый фланг* — сул як флангны каплау; 4. саклау; *эта ель не может прикрыть от дождя* — бу чыршы яңгырдан саклый алмый; 5. *перен.* каплап калу, яшерү; *прикрыть чей-л. обман* — кемнең дә булса ялганын яшерү; 6. *разг. фам.* ябу, бетерү; *прикрыть магазин* — магазинны ябу (бөтенләйгә ябу мәгънәсендә).

**ПРИКРЫ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. каплану, ябыну; *прикрыться одеялом* — юрган ябыну; 2. *разг.* ябылу; *дверь прикрылась* — ишек ябылды; 3. *перен.* качып калу, яшеренеп калу; *прикрыться хвастливыми словами* — мактанулы сүзләр белән яшеренеп калу; 4. *разг. фам.* ябылу, бетү; *ларёк прикрылся* — ларёк ябылды.

**ПРИ'КУП** *м. только ед.*— к. прикупить.

**ПРИКУПА'ТЬ** *несов.*— к. прикупить.

**ПРИКУПА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— өстәмә рәвештә сатып алыну, сатып алып кушылу.

**ПРИКУПИ'ТЬ** *сов.*— өстәмә рәвештә сатып алу, сатып алып кушу.

**ПРИКУ'ПКА** *ж. мн.* нет, *разг.*— к. прикупить.

**ПРИКУ'РИВАТЬ** *несов.*— к. прикурить.

**ПРИКУРИ'ТЬ** *сов.*— кабызу, (бер папиросны икенчесеннән) кабызып алу.

**ПРИКУРНУ'ТЬ** *сов.*— к. прикорнуть.

**ПРИКУСИ'ТЬ** *сов.*— 1. тешләү; *прикусил язык себе* — телемне тешләдем; 2. кыстыру, эләктереп алу; *прикусил палец щипцами* — бармагымны кыскычка кыстырдым; 3. *разг. фам. (немного съесть)* ашап алу, капкалап алу.

**ПРИКУ'СЫВАТЬ** *несов.*— 1. к. прикусить; 2. *разг.* тешләп-тешләп алу, кабып-кабып алу, аз-азлап кабу, капкалау.

**ПРИЛА'ВОК** *м.*— 1. *(в магазине)* прилавка; 2. *обл. (скамейка)* ян сәке, уша. ◇ **Работник прилавка** — сатучы (кибеттә).

**ПРИЛАГА'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *лингв.*— сыйфатлык.

**ПРИЛАГА'ТЕЛЬНЫЙ**: **имя прилагательное или прилагательное** *грам.*— сыйфат.

**ПРИЛАГА'ТЬ** *несов. книж.*— к. приложить 3, 4, 5.

**ПРИЛАГА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.*— 1. теркәлү (мәсәлән, гаризага справка); 2. куелу (мәсәлән, көч); 3. кулланылу (мәсәлән, практикада).

**ПРИЛА'ДИТЬ** *сов.* — җайлау, рәтләү, ипләү, рәтләп кую, җайлап кую, ипләп кую.

**ПРИЛА'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. приладить.

**ПРИЛА'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — җайлану, рәтләнү, ипләнү, рәтләп куелу, җайлап куелу, ипләп куелу.

**ПРИЛАСКА'ТЬ** *сов.* — иркәләү, сөю.

**ПРИЛАСКА'ТЬСЯ** *сов.* — иркәләнү, иркәләнеп сыену.

**ПРИЛА'СТИТЬСЯ** *сов. простореч.* — к. приласкаться.

**ПРИЛГА'ТЬ** *сов. разг.* — ялган сүзләр кушып сөйләү, арада ялганлап алу, арада ялган кыстыру.

**ПРИЛГНУ'ТЬ** *сов. разг.* — (арада) ялганлап алу, ялган кыстырып кую.

**ПРИЛЕГА'ТЬ** *несов.* — 1. сыланып тору; *платье хорошо прилегает* — күлмәге бик яхшы сыланып тора; 2. *книж.* барып тоташу; *поле прилегает к лесу* — басу урманга барып тоташа; 3. тиеп тору, орынып тору; *полка прилегает к стене* — киштә стенага орынып тора; 4. *книж. устар.* к. прилежать 1.

**ПРИЛЕЖА'НИЕ** *ср. мн.* нет — тырышу, тырышлык.

**ПРИЛЕЖА'ТЬ** *несов. книж. устар.* — 1. тырышып...-у, күнел куеп...-у; *прилежать к математике* — математиканы тырышып өйрәнү; 2. к. прилегать 2.

**ПРИЛЕЖА'ЩИЙ** — 1. *книж. устар.* к. прилежный; 2. *мат.* чиктәш; *прилежащая сторона* — чиктәш як.

**ПРИЛЕ'ЖНО** *нареч.* — тырышып, күнел куеп.

**ПРИЛЕ'ЖНОСТЬ** *ж. мн.* нет — к. прилежание.

**ПРИЛЕ'ЖНЫЙ** — тырыш, тырышучан, күнел куеп...-; *прилежный ученик* — тырыш укучы.

**ПРИЛЕЗА'ТЬ** *несов. разг.* — к. прилезть.

**ПРИЛЕ'ЗТЬ** *сов. разг.* — 1. үрмәләп керү, (үрмәләп кереп) тулу; *в палатку прилезли муравьи* — палаткага кырмыскалар (кереп) тулган; 2. *простореч. фам.* керү, килү; *зачем ты прилез ко мне в комнату?* — нигә син минем бүлмәгә кердең? *медведь прилез в пчельник* — аю умарталыкка кергән.

**ПРИЛЕПИ'ТЬ** *сов.* — 1. ябыштыру, ябыштырып кую; *прилепить марку* — марка ябыштыру; 2. *разг. фам.* кадау, кадап кую; *прилепить к шляпе бант* — эшләпәгә бант кадап кую.

**ПРИЛЕПИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. ябышу; *марка хорошо прилепилась* — марка яхшы ябышты; 2. *перен. разг.* урнашу; *на склоне горы прилепился хуторок* — тау битенә кечкенә генә хутор урнашкан.

**ПРИЛЕ'ПЛИВАТЬ** *несов.* — к. прилепить.

**ПРИЛЕ'ПЛИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. ябышу; 2. *страд.* ябыштырылу.

**ПРИЛЕПЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. прилепить.

**ПРИЛЕПЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — к. прилепливаться.

**ПРИЛЁТ** *м. мн.* нет — очып килү.

**ПРИЛЕТА'ТЬ** *несов.* — к. прилететь.

**ПРИЛЕТЕ'ТЬ** *сов.* — 1. (очып) килү, (очып) килеп житү; *прилетели ласточки* — карлыгачлар килде; 2. (очып) керү; *муха прилетела в комнату* — бүлмәгә чебен керде; 3. *перен. разг. (быстро приехать, примчаться)* тиз килеп житү, ашыгыч рәвештә кайту, чаптырып килеп житү, чабып килеп житү, очып кайту.

**ПРИЛЁТНЫЙ** — күчмә...; *прилётные птицы* — күчмә кошлар.

**ПРИЛЕ'ЧЬ** *сов.* — 1. (бераз) яту, ятып алу; *прилечь отдохнуть* — бераз ял итәргә яту; 2. сөрлегү; *рожь после дождя прилегла* — арыш (лар) яңгырдан соң сөрлеккән; 3. кую; *прилёг ухом к рельсу* — колагымны рельска куйдым; 4. к. прилегать 1.

**ПРИЛИ'В** *м.* — 1. *(подъем уровня моря)* (су) арту, (су) күтәрелү, күтәрелеш; 2. *перен.* агылу, җыелу, арту, туплану; *прилив народу* — халыкның җыелуы (артуы); 3. *перен.* күтәрелү, күтәрелеш; *прилив революции* — революциянең күтәрелүе. ◇ **Прилив крови к голове** — башка кан саву, башка кан йөгерү.

**ПРИЛИВА'ТЬ** *несов.* — к. прилить.

**ПРИЛИВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *простореч.* к. прилиться; 2. *страд.* (агызып) өстәп салыну.

**ПРИЛИЗА'ТЬ** *сов.* — 1. *(языком)* ялап тигезләү; 2. *перен. разг.* ялагандай итеп тигезләп кую, ялагандай итеп тарап кую.

**ПРИЛИЗА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — ялагандай итеп чәчне тарап кую, тип-тигез (шома) итеп чәчне тарап кую.

**ПРИЛИ'ЗЫВАТЬ** *несов.* — к. прилизать.

**ПРИЛИ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. прилизаться; 2. *страд.* ялап тигезләнү; ялагандай итеп тигезләп куелу, ялагандай итеп тарап куелу, шома итеп тарап куелу.

**ПРИЛИ'КА** *ж.*: **для прилики** *разг. фам.* — әдәп йөзеннән, әдәп саклап.

**ПРИЛИПА'ЛА** *м.* и *ж. разг. фам.* — бәйләнчек, бәйләнүчән.

**ПРИЛИПА'ТЬ** *несов.* — к прилипнуть.

**ПРИЛИ'ПНУТЬ** *сов.* — 1. ябышу; ябышып калу, сылану; 2. *фам. (о болезнях)* йогу; 3. *перен. разг. фам.* бәйләнү, сагыз булу. ◇ **Прилипе́ язык к гортани** — телем тамагыма ябышты (бер сүз дә әйтә алмадым).

**ПРИЛИ'ПЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.* — 1. ябышучан булу, сыланучан булу; 2. *фам.* йогышлылык, йогышлы булу; 3. *перен. фам.* бәйләнчек булу, бәйләнүчән булу, сагыз булу.

**ПРИЛИ'ПЧИВЫЙ** *разг.* — 1. ябышкак, ябышучан; 2. *фам. (о болезнях)* йогышлы; 3. *перен. фам.* бәйләнчек, бәйләнүчән.

**ПРИЛИ'СТНИК** *бот.* — төпчек яфрак (зур яфрак төбендәге кечкенә яфрак).

**ПРИЛИ'ТЬ** *сов.* — 1. агып килеп житү, агып барып житү; *вода прилила к камню* — су таш янына агып килеп житте; 2. *разг.* (агызып) өстәп салу, өсти төшү; *прилей в бутылку квасу* — шешәгә квас өсти төш. ◇ **Кровь прилила к голове** — башка кан йөгерде (кан сауды).

**ПРИЛИ'ТЬСЯ** *сов.* — к. прилить 1.

**ПРИЛИ'ЧЕСТВОВАТЬ** *несов. книж. устар.* — килешү, яраү, урынлы булу; *ему*

*не приличествует быть грубым* — ана дорфалык килешми, ана тупас булырга ярамый.

**ПРИЛИ'ЧИЕ** *ср.* — әдәп; *для приличия* — әдәп йөзеннән, әдәп саклап.

**ПРИЛИ'ЧНЫЙ** — **1.** әдәпле, тәрбияле; *приличный человек* — әдәпле кеше; **2.** *устар.* (*соответствующий*) урынлы, туры килә торган, туры килеп тора торган; тиешле, килешле; **3.** *разг.* шактый яхшы; *в знач. сказ.* начар түгел; *пальто приличное* — пальто шактый яхшы, пальто начар түгел; **4.** шактый зур; *получает приличную зарплату* — шактый зур эш хакы ала.

**ПРИЛОВЧИ'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.* — өйрәнеп житү, күнегеп житү, остарып житү.

**ПРИЛОЖЕ'НИЕ** I *ср.* — **1.** *только ед.* (*действие*) к. приложить; **2.** кушымта, өстәмә; *эта книга дана в качестве приложения* — бу китап өстәмә итеп бирелгән.

**ПРИЛОЖЕ'НИЕ** II *ср. грам.* — өстәмә сүз.

**ПРИЛОЖИ'ТЬ** *сов.* — **1.** кую; *приложить руку к сердцу* — кулны күкрәккә кую; **2.** ябу, ябыштыру; *приложить пластырь к руке* — кулга пластырь ябу; **3.** теркәү; *приложить к заявлению справку* — гаризага справка теркәү; **4.** кую, салу; *приложить силы* — көч кую; **5.** *книж.* куллану; *приложить теорию на практике* — теорияне практикада куллану. ◇ **Приложить печать** — печать басу. **Ума не приложу** — акылым житми, аңлап житә алмыйм. **Приложить руку** *перен.* — кул тидерү, катнашу.

**ПРИЛОЖИ'ТЬСЯ** *сов.* — **1.** *книж. шутл.* (*почтительно поцеловать*) олылап (хөрмәтләп) үбү; **2.** *разг.* (*нацелиться*) төзәү, төбәү. ◇ **Приложиться ухом** — колак салу. **Остальное приложится** — калганы булыр, калганы һичшиксез булыр.

**ПРИЛУЧИ'ТЬ** *сов. обл.* — кызыктыру, кызыктырып китерү.

**ПРИЛЫГА'ТЬ** *несов. разг. устар.* — к. прилгать.

**ПРИЛЬНУ'ТЬ** *сов.* — сырышу, сарылу; *ребёнок прильнул к матери* — бала анасына сарылды. ◇ **Прильнуть губами** — иренне тидерү, үбү.

**ПРИЛЯ'ПАТЬ** *сов. просторен.* — килешсез итеп кадап кую; килешсез итеп тагып (элеп) кую.

**ПРИЛЯ'ПЫВАТЬ** *несов. просторен.* — к. приляпать.

**ПРИЛЯ'ПЫВАТЬСЯ** *несов. страд. просторен.* — килешсез итеп кадап куелу, килешсез итеп тагып (элеп) куелу.

**ПРИ'МА** *ж.* — прима (**1.** *муз.* гамманың төп авазы; **2.** *муз.* скрипканың, виолончельнең беренче нечкә кылы; **3.** *муз.* бер үк төрле авазларның, тоннарның, үзара туры килүе; **4.** ансамбльдә беренче партияне алып баручы кеше яки музыка коралы; **5.** *банк. торг.* почта аша жибәрелә торган вексельнең беренче экземпляры).

**ПРИ'МА-БАЛЕРИ'НА** *ж. театр.* — прима-балерина (беренче рольләрне башкаручы балерина).

**ПРИМАДО'ННА** *ж. театр.* — примадонна (операда беренче рольләрне башкаручы актриса).

**ПРИМА'ЗАТЬ** *сов.* — **1.** *разг.* майлап шомартып кую (чәчне); **2.** (замазка, балчык белән) сылап кую, сылап ябыштыру, сылап ябыштырып кую.

**ПРИМА'ЗАТЬСЯ** *сов.* — **1.** *разг.* (чәчне) майлап тарап кую; **2.** *перен. разг. фам.* (*в компанию*) тыкшыну, тагылу.

**ПРИМА'ЗЫВАТЬ** *несов.* — к. примазать.

**ПРИМА'ЗЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. примазаться.

**ПРИМА'К, ПРИМА'КА** *м. обл. устар.* — йортка кергән кеше (өйләнешкәннән соң хатын йортына күчкән ир).

**ПРИМА'КИВАТЬ** *несов. разг.* — ману, манып-манып алу.

**ПРИМАКНУ'ТЬ** *сов. разг.* — ману, манып алу.

**ПРИМА'ЛЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. примолоть.

**ПРИМА'ЛЫВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — өстәмә рәвештә тарттырылу, тарттырып өстәлү (он турында).

**ПРИМА'НИВАТЬ** *несов. разг.* — к. приманить.

**ПРИМА'НИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — (кызыктырып) чакырып китерелү.

**ПРИМАНИ'ТЬ** *сов. разг.* — **1.** (кызыктырып) чакыру, чакырып китерү; *приманить кур* — тавыкларны чакырып китерү; **2.** (*привлечь к себе*) үзенә карату.

**ПРИМА'НКА** *ж.* — **1.** жим, алдавыч; *червяк — лучшая приманка для окуня* — алабуга өчен иң яхшы жим — суалчан; **2.** *перен.* алдавыч, кызыктыргыч.

**ПРИМА'НОЧНЫЙ** *спец.* — алдавыч..., кызыктыргыч...; *приманочные растения* — алдавыч үсемлекләр.

**ПРИМА'НЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *устар.* — к. заманчивость.

**ПРИМА'НЧИВЫЙ** *устар.* — к. заманчивый.

**ПРИМА'РКА** *ж. торг.* — ташлама, скидка (савытка ягыла яки ябыша торган товарларның авырлыгыннан).

**ПРИМА'СЛИВАТЬ** *несов. разг.* — к. примаслить.

**ПРИМА'СЛИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — майлап тигезләп куелу, майлап шомартып куелу.

**ПРИМА'СЛИТЬ** *сов. разг.* — майлап тигезләп кую, майлап шомартып кую.

**ПРИМАСТЕРИ'ТЬ** *сов. просторен.* — к. приладить.

**ПРИМА'Т** *м. мн.* нет, *книж. филос.* — примат (беренчеллек, өстенлек).

**ПРИМА'ТЫ** *мн. зоол.* — приматлар (югары төзелешле имезүчеләр отряды — кешеләр, маймыллар һәм ярыммаймыллар).

**ПРИМА'ТЫВАТЬ** *несов.* — к. примотать.

**ПРИМА'ТЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — өстәп чорналу, өстәмә рәвештә чорналу.

**ПРИМА'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. примочить.

**ПРИМА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — чылатып куелу, сулап куелу.

**ПРИМА'ЩИВАТЬ** *несов.* — к. примостить.

**ПРИМА'ЩИВАТЬСЯ** *несов.* — **1.** *разг.* к. примоститься; **2.** *страд.* урнаштырылу.

**ПРИМЕЖЕВА'ТЬ** *сов. спец.* — өстәмә рә-

вештә кисеп бирү, өстәп кисеп бирү (җир участогы турында).

**ПРИМЕЖЁВЫВАТЬ** *несов. спец.* — к. примежевать.

**ПРИМЕЖЁВЫВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.* — өстәмә рәвештә кисеп бирелү, өстәп кисеп бирелү (җир участогы турында).

**ПРИМЕЛЬКА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — таныш булып бетү, танышка әйләнү; күз иләшеп бетү.

**ПРИМЕНЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. (*действие*) к. применить; 2. кулланылыш; 3. (*действие*) к. примениться. ◇ **В применении** *к чему* —... карата алганда,... туры китереп алганда..

**ПРИМЕНИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — кулланырлык булу, кулланырлык дәрәҗәдә булу.

**ПРИМЕНИ'МЫЙ** *книж.* — кулланырлык, ярарлык, кулланырга яраган, кулланырга мөмкин булган.

**ПРИМЕНИ'ТЕЛЬНО** *нареч.* — карата, карап, туры китереп; *применительно к данному случаю* — бу очракка карата; *действовать применительно к обстановке* — обстановкага карап эш итү.

**ПРИМЕНИ'ТЬ** *сов.* — куллану, файдалану.

**ПРИМЕНИ'ТЬСЯ** *сов.* — җайлашу, иплэшү.

**ПРИМЕНЯ'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — кулланылу, кулланылыш.

**ПРИМЕНЯ'ТЬ** *несов.* — к. применить.

**ПРИМЕНЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. примениться; 2. *страд.* кулланылу.

**ПРИМЕ'Р** *м.* — 1. үрнәк; *брать пример с кого-либо* — кемнән дә булса үрнәк алу; *служить примером* — үрнәк булып тору; 2. мисал; *привести пример* — мисал китерү; 3. калдык (ялгыш үлчәү аркасында килеп чыккан калдык). ◇ **Для примера** *разг.* — үрнәк итеп, үрнәк булсын өчен, гыйбрәт өчен. **К примеру** — мәсәлән. **По примеру** —... тәҗрибәсеннән чыгып, ...-гыча,... үрнәге буенча; *по примеру прошлых лет* — үткән еллар тәҗрибәсеннән чыгып. **Не в пример** — к. невпример.

**ПРИМЕРЕ'ТЬ** *сов. просторeч.* — үлеп бетү.

**ПРИМЕРЕ'ЩИТЬСЯ** *сов. разг.* — к. помещиться.

**ПРИМЕРЗА'ТЬ** *несов.* — к. примёрзнуть.

**ПРИМЁРЗЛЫЙ** *разг.* — туңып ябышкан, туңып ябышып каткан.

**ПРИМЁРЗНУТЬ** *сов.* — туңып ябышу, туңып ябышып кату.

**ПРИМЕ'РИВАТЬ** *несов.* — к. примерять.

**ПРИМЕ'РИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. примериться; 2. *страд.* үлчәнү, үлчәп каралу, киеп үлчәп каралу; 3. *страд.* өстәп үлчәнү, өстәмә рәвештә үлчәнү.

**ПРИМЕ'РИТЬ** *сов.* — 1. үлчәү, үлчәп карау, киеп карау, киеп үлчәп карау; *примерить платье* — күлмәкне киеп карау; *семь раз примерь, а один раз отрежь* — җиде кат үлчә, бер кат кис; 2. *просторeч.* үлчәү, өстәп үлчәү, өстәмә рәвештә үлчәү; *примерь ещё метр сукна* — тагын бер метр сукно үлчә.

**ПРИМЕ'РИТЬСЯ** *сов. разг.* — җайлашу, чамалап карау.

**ПРИМЕ'РКА** *ж.* — 1. *только ед.* (*действие*) к. примерить 1; 2. *порт.* примерка (киеп, үлчәп карарга тиеш булган кием); *портной принёс примерку* — тегүче примерканы китерде.

**ПРИМЕ'РНО** *нареч.* — 1. үрнәк булырлык итеп; үрнәк булырлык дәрәҗәдә; *примерно вести себя* — үзеңне үрнәк булырлык итеп тоту; 2. якынча, чама белән; диярлек; *мы примерно так и договорились* — без чама белән шулай килешкән идек тә.

**ПРИМЕ'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. үрнәк булырлык булу; 2. якынчалык, якынча булу, чама белән эшләнү; *примерность расчётов* — исәп-хисапларның якынча булуы.

**ПРИМЕ'РНЫЙ** — 1. (*образцовый*) үрнәк булырлык; 2. (*приблизительный*) якынча, чама белән эшләнгән.

**ПРИМЕРЯ'ТЬ** *несов.* — к. примерить.

**ПРИМЕРЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг.* к. примериться; 2. *страд.* к. примериваться 2.

**ПРИМЕСИ'ТЬ** *сов.* — катыштырып изү, өстәп изү, кушып изү.

**ПРИМЕ'СОК** *м. обл.* — катнаштырылган әйбер (нәрсә), кушылган әйбер (нәрсә).

**ПРИМЕСТИ'** *сов. разг.* — себереп җыю, себереп китерү.

**ПРИ'МЕСЬ** *ж.* — катнашма.

**ПРИМЕ'ТА** *ж.* — 1. (*отличительный признак*) билге, тамга; 2. (*в суевериях*) галәмәт; *это — дурная примета* — бу яхшыга түгел, бу начар галәмәт. ◇ **На примете** (*иметь, быть*) — күз алдында тоту. **По народным приметам** — халык әйтүе буенча, халык тәҗрибәсе буенча, халык сынавы буенча.

**ПРИМЕТА'ТЬ** I *несов. разг.* — к. примести.

**ПРИМЕТА'ТЬ** II *сов. обл.* — өю, өеп кую; *приметать снег к забору* — карны койма янына өю.

**ПРИМЕТА'ТЬ** III *сов. порт.* — күкләп кую, типчеп кую.

**ПРИМЕТА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — себереп җыелу, себереп китерелү.

**ПРИМЕ'ТИТЬ** *сов. разг.* — күрү, күреп алу, сизү, сизеп алу, игътибар итү.

**ПРИМЕ'ТЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.* — күзәтүчән булу, күзәтүчәнлек, сизгер булу, сизгерлек.

**ПРИМЕ'ТЛИВЫЙ** *разг.* — күзәтүчән, сизгер.

**ПРИМЕ'ТНО** *нареч.* — сизелерлек, сизелерлек дәрәҗәдә.

**ПРИМЕТНУ'ТЬ** *сов. порт. просторeч.* — к. приметать III.

**ПРИМЕТНУ'ТЬСЯ** *сов. обл. просторeч.* — ияру, килеп кушылу.

**ПРИМЕ'ТНЫЙ** — 1. күзгә бәрелеп тора торган, бик ачык, сизелеп тора торган, беленеп тора торган, аерылып тора торган, сизелерлек; *приметные успехи* — күзгә бәрелеп торган уңышлар; 2. *разг.* билгеле, атаклы, күренекле; *человек он приметный* — ул күренекле кеше; 3. *обл.* тамгалы; *конь приметный, со звездой на лбу* — тамгалы ат, маңгаенда кашкасы бар.

**ПРИМЁТЫВАТЬ** I *несов. обл.*— к. приметать II.

**ПРИМЁТЫВАТЬ** II *несов. порт.*— к. приметать III.

**ПРИМЁТЫВАТЬСЯ** I *несов. страд. обл.*— өелү, өеп куелу.

**ПРИМЁТЫВАТЬСЯ** II *несов. страд. порт.* — күкләп куелу, типчеп куелу.

**ПРИМЕЧА'НИЕ** *ср. книж.*— 1. искәрмә; *примечания помещены в конце книги* — искәрмәләр китапның ахырында урнаштырылган; 2. *устар.* игътибар, игътибар итү; *это явление достойно особого примечания* — бу күренеш зур игътибарга лаеклы.

**ПРИМЕЧА'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— игътибар итәрлек булу; игътибарга лаеклы булу; күренеклелек.

**ПРИМЕЧА'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.*— игътибар итәрлек, игътибарга лаеклы; күренекле; *примечательный факт* — игътибар итәрлек факт; *примечательные лица* — күренекле кешеләр.

**ПРИМЕЧА'ТЬ** *несов. разг.*— 1. к. приметить; 2. *(наблюдать)* күзәтү, карау, күзәтеп тору.

**ПРИМЕША'ТЬ** *сов.*— 1. кушу, катыштыру, бутап кушу; *примешать соли в сахар* — шикәргә тоз катыштыру; 2. *перен. разг.* катнаштыру, бутау; *и меня к этому делу примешал* — мине дә бу эшкә бутады.

**ПРИМЕ'ШИВАТЬ** I *несов.*— к. примесить.

**ПРИМЕ'ШИВАТЬ** II *несов.*— к. примешать.

**ПРИМЕ'ШИВАТЬСЯ** I *несов. страд.*— катыштырып изелү, өстәп изелү, кушып изелү.

**ПРИМЕ'ШИВАТЬСЯ** II *несов. страд.*— кушылу, катыштырылу.

**ПРИМИНА'ТЬ** *несов.*— к. примять.

**ПРИМИНА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. примяться; 2. *страд.* изелү; тапталу.

**ПРИМИРЕ'НЕЦ** *м. полит. презрит.*— килешүчән кеше (принципиаль характердагы фикер башкалыклары булганда, буржуазия интересларын күздә тотып, урта линияне табуга омтылучы оппортунист).

**ПРИМИРЕ'НИЕ** *ср.*— 1. *(действие)* к. примирить, примириться; 2. тынычлык, татулык.

**ПРИМИРЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— килешү, күнү, килешүчәнлек, күнүчәнлек.

**ПРИМИРЕ'НЧЕСКИЙ** *полит.*— килешүчәнлек...-ы; *примиренческая политика* — килешүчәнлек политикасы.

**ПРИМИРЕ'НЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *полит.*— килешүчәнлек.

**ПРИМИРИ'ТЕЛЬ** *м. книж.*— килештерүче, татулаштыручы.

**ПРИМИРИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.*— татулаштыра торган, килештерә торган, татулашуга (килешүгә) юнәлдерелгән.

**ПРИМИРИ'ТЬ** *сов.*— килештерү, татулаштыру.

**ПРИМИРИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *(помириться)* килешү, татулашу; 2. буйсыну, баш ию; күнү, риза булу; *примириться с судьбой* — язмышка буйсыну (баш ию).

**ПРИМИРЯ'ТЬ** *несов.*— к. примирить.

**ПРИМИРЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. примириться; 2. *страд.* килештерелү, татулаштырылу.

**ПРИМИТИ'В** *м. книж.*— примитив (1. гади, тупас эшләнгән әйбер; 2. башлангыч, гади күренеш; 3. тупас эшләнгән борынгы сәнгать әсәре).

**ПРИМИТИВИ'ЗМ** *м. мн.* нет — 1. *искус.* примитивизм (буржуаз сәнгатьтә художестволы образ иҗат итүдә артык гадиләштерелгән алымнар куллана торган һәм тәшенкелеккә бирелүне чагылдыра торган агым); 2. *книж.* примитивлык, примитивизм (катлаулы мәсьәләләргә чиктән тыш гади караш).

**ПРИМИТИ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. примитивлык, гадилек; 2. *перен.* примитивлык, тупаслык, тар карашлылык; 3. примитивлык, борынгылык.

**ПРИМИТИ'ВНЫЙ** — 1. примитив, гади; *примитивный механизм* — гади механизм; 2. *перен.* примитив, тупас, тар карашлы; *примитивный человек* — тар карашлы кеше; 3. *книж.* примитив, борынгы; *примитивные племена* — борынгы кабиләләр.

**ПРИМКНУ'ТЬ** *сов.*— 1. янәшә китереп кую, якынайту, елыштыру; *примкнуть доски одна к другой* — такталарны бер-берсенә янәшә китереп кую; 2. *устар. редко* кушу, кертү; *может быть, к ним следует примкнуть и Манилова* (Гоголь) — бәлки, алар арасына Маниловны да кертергә кирәктер; 3. фикергә кушылу; *примкнуть к большинству* — күпчелекнең фикеренә кушылу.◇ **Примкнуть штык** *воен.*— штыкны кидерү (винтовкага).

**ПРИМОКНУ'ТЬ** *сов.* — к. примакнуть.

**ПРИМОЛА'ЧИВАТЬ** *несов. разг.*— к. примолотить.

**ПРИМОЛА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— өстәмә рәвештә сугылу (ашлык турында).

**ПРИМО'ЛВИТЬ** *сов. разг.*— өстәп әйтү.

**ПРИМОЛКА'ТЬ** *несов. разг.*— к. примолкнуть.

**ПРИМО'ЛКНУТЬ** *сов.*— тынып калу, шып туктау, сөйләшүдән (елаудан һ. б.) туктау, тыну.

**ПРИМОЛОТИ'ТЬ** *сов. разг.*— өстәмә рәвештә ашлык сугу, ашлык сугып өстәү.

**ПРИМОЛО'ТЬ** *сов. разг.*— өстәп тарттыру (он турында).

**ПРИМОРА'ЖИВАТЬ** *несов.*— к. приморозить.

**ПРИМОРО'ЗИТЬ** *сов.*— туңдырып ябыштыру.

**ПРИМО'РСКИЙ** — диңгез буе...-ы; диңгез буендагы; *приморский район* — диңгез буе районы.

**ПРИМО'РЬЕ** *ср.*— диңгез буе.

**ПРИМОСТИ'ТЬ** *сов.*— 1. *просторечн.* өстәмә рәвештә таш җәю; 2. *разг.* урнаштыру, кую; *примостить чемодан на краю полки* — чемоданны киштәнең кырыена урнаштыру.

**ПРИМОСТИ'ТЬСЯ** *сов.*— урнашу.

**ПРИМОТА'ТЬ** *сов.*— өстәп чорнау, өстәмә рәвештә чорнау.

**ПРИМОЧИ'ТЬ** *сов.*— чылатылган әйбер

ябу, юеш әйбер ябу; *примочить ушиб холодной водой* — бәрелгән җиргә салкын суда чылатылган әйбер ябу.

**ПРИМО'ЧКА** *ж.*— 1. *(лекарство)* примочка (чүпрәккә, мамыкка сеңдереп, авырткан җиргә куела торган сыек дару); 2. *только ед. (действие)* к. примочить.

**ПРИМСТИ'ТЬСЯ** *сов. безл. обл.*— күзгә күренү, хыялга килү.

**ПРИ'МУЛА** *ж.*— нәвруз чәчәге, примула.

**ПРИ'МУС** *м.*— примус (аш пешерү приборы).

**ПРИ'МУСНЫЙ** — примус...-ы; *примусная иголка* — примус энәсе.

**ПРИМЧА'ТЬ** *сов. разг.*— 1. очыртып китерү, бик тиз китереп җиткерү; 2. *простореч.* к. примчаться.

**ПРИМЧА'ТЬСЯ** *сов.*— чабып (чаптырып) килеп җитү, очыртып килеп җитү, бик тиз килеп җитү.

**ПРИМЫКА'НИЕ** *ср.*— 1. *только ед. (действие)* к. примыкать; 2. *грам.* янәшәлек (бәйләнеше).

**ПРИМЫКА'ТЬ** *несов.*— 1. к. примкнуть; 2. янәшә булу, барып тоташу; *поле примыкает к лесу* — кыр урманга барып тоташа; 3. *грам.* янәшәлек юлы белән бәйләнү.

**ПРИМЫ'СЛИТЬ** *сов.*— 1. үзеннән өстәү, үзеннән чыгару, үзеннән чыгарып өстәү, үзеннән арттырып сөйләү; *примыслить ложь к правде* — дөрескә ялганны үзеннән чыгарып өстәү; 2. *устар. (добыть себе)* табу.

**ПРИМЫШЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. примыслить.

**ПРИМЫШЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. үзеннән өстәлү, үзеннән чыгарып өстәлү, үзеннән арттырылу; 2. *устар.* табылу.

**ПРИМЯ'ТЬ** *сов.*— 1. изү, таптау; *примять подушки* — мендәрләрне изү; *примять траву* — үләнне таптау; 2. сөрлектерү; *градом примяло рожь* — арышны боз сөрлектергән.

**ПРИМЯ'ТЬСЯ** *сов.*— изелү, тапталу.

**ПРИНАДЛЕЖА'ТЬ** *несов.*— 1. ...-ныкы булу, ...кулында булу; *книга принадлежит библиотеке* — китап китапханәнеке; 2. булу, тору; *он принадлежит к союзу металлистов* — ул металлистлар союзында тора; 3. исәпләнү, саналу; *он принадлежит к людям весёлым* — ул шат кешеләрдән исәпләнә (ул шат кеше).◇ **Ему принадлежит большое будущее** — аны зур киләчәк көтә. **Спорту принадлежит большое будущее** — спорт киләчәктә киң колач алачак. **Русскому учёному Попову принадлежит честь открытия радио** — радионы ачу даны рус галиме Поповка кайтып кала, радионы беренче буларак рус галиме Попов ачкан.

**ПРИНАДЛЕ'ЖНОСТЬ** *ж.*— 1. әйбер, кирәк- яраклар, әсбаплар; *канцелярские принадлежности* — канцелярия кирәк- яраклары; 2. *только ед. (действие)* к. принадлежать 2; 3. *только ед. книж. устар.* ...-ныкы; *этот дом — принадлежность нашей семьи* — бу йорт безнең семьяныкы; 4. *только ед. книж.* кисәк, өлеш; *являться необходимой принадлежностью чего-л.*— берәр нәрсәнең иң кирәкле өлеше булып тору. ◇ **По принадлежности** *офиц.*— тиешлесенә, тиешле кешесенә, тиешле урынга.

**ПРИНАЖА'ТЬ** *сов. разг.*— 1. баса төшү, кыса төшү, аз гына басу, аз гына кысу; 2. *простореч. фам.* к. налечь.

**ПРИНАКОПИ'ТЬ** *сов. разг. фам.*— акрынлап җыю, аз-азлап җыю, аз-азлап туплау.

**ПРИНАЛЕ'ЧЬ** *сов. разг.*— 1. җиңелчә генә таяну, аз гына таяну, терәлеп тору, ята төшү; 2. тырышып...-а башлау, күңел куеп...-а башлау; *приналечь на учёбу* — тырышып укый башлау.

**ПРИНАНИМА'ТЬ** *несов. разг. фам.*— к. принанять.

**ПРИНАНЯ'ТЬ** *сов. разг. фам.*— к. нанять.

**ПРИНАРЯДИ'ТЬ** *сов. разг.*— матур итеп киендерү, купшы итеп киендерү, чын ясау итеп киендерү.

**ПРИНАРЯДИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— матур итеп киенү, купшы киенү, чын ясау булып киенү.

**ПРИНАРЯЖА'ТЬ** *несов. разг.*— к. принарядить.

**ПРИНАРЯЖА'ТЬСЯ** *несов. разг.*— 1. к. принарядиться; 2. *страд.* купшы киендерелү, матур итеп киендерелү.

**ПРИНАХМУ'РИТЬСЯ** *сов. разг. нар.-поэт.*— каш җыерып алу, чырай сытып кую.

**ПРИНЕВО'ЛИВАТЬ** *несов. разг.*— к. приневолить.

**ПРИНЕВО'ЛИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— 1. мәҗбүр ителү, ирексезләнү; 2. *устар.* коллыкка төшерелү.

**ПРИНЕВО'ЛИТЬ** *сов. разг.*— 1. мәҗбүр итү, ирексезләү; коллыкка төшерү.

**ПРИНЕСТИ'** *сов.*— 1. китерү, күтәреп китерү, (күтәреп) алып килү; *принести книгу* — китапны алып килү; 2. тудыру, балалау, китерү; *кошка принесла пять котят* — мәче биш бала китерде; 3. бирү; *яблоня принесла очень много яблок* — алмагач бик күп алма бирде; 4. китерү, бирү; *принести пользу* — файда китерү. ◇ **Принести благодарность** — рәхмәт белдерү. **Принести повинную** — гаебен тану. **Принести клятву** — ант итү. **Принести в дар** — бүләк итеп бирү. **Принести жалобу** — жалоба бирү. **Зачем тебя сюда принесло?** *простореч. фам.*—нигә син монда килдең? ни пычагыма син монда килдең? **Принести протест** — протест белдерү, протест ясау. **Принести в жертву** — корбан итү. **Принести извинения** — гафу үтенү.

**ПРИНЕСТИ'СЬ** *сов. разг.*— 1. (бик тиз) килү, килеп җитү; *зачем ты сюда принеслась?* — нигә син бирегә килеп җиттең? 2. килү, ишетелү; *издалека принеслись звуки пения* — ерактан җырлау тавышлары ишетелде.

**ПРИНИЖА'ТЬ** *несов.*— к. принизить.

**ПРИНИЖА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. кимсетелү; 2. түбәнәйтелү, кечерәйтелү.

**ПРИНИ'ЖЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — кимсетелгән булу, кимсетелгәнлек, кимсетелү.

**ПРИНИЗА'ТЬ** *сов.*— өстәп тезү, өстәмә рәвештә тезү.

**ПРИНИ'ЗИТЬ** *сов.*— 1. *(унизить)* кимсе-

тү; 2. *разг.* (*умалить*) түбәнәйтү, кечерәйтү, төшерү.

**ПРИНИ'ЗЫВАТЬ** *несов.*— к. принизать.

**ПРИНИ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— өстәп тезелү, өстәмә рәвештә тезелү.

**ПРИНИКА'ТЬ** *несов.*— к. приникнуть.

**ПРИНИ'КНУТЬ** *сов.*— 1. посу; *заяц приник за кустом* — куян куак артына посты; 2. сарылу, сыену; *ребёнок приник к матери* — бала анасына сыенды. ◇ **Приникнуть ухом к...**—...-га колакны кую; *приникнуть ухом к двери* — колакны ишеккә кую.

**ПРИНИМА'ТЬ** *несов.*— к. принять.

**ПРИНИМА'ТЬСЯ** I *несов.*— к. приняться.

**ПРИНИМА'ТЬСЯ** II *несов. страд.*— 1. алыну; 2. каршы алыну; кабул ителү.

**ПРИНОРА'ВЛИВАТЬ** *несов.*— к. приноровить.

**ПРИНОРА'ВЛИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. приноровиться; 2. *страд.* туры китерелү, җайлаштырылу.

**ПРИНОРОВИ'ТЬ** *сов.*— туры китерү, җайлаштыру, җайлау, ипләү.

**ПРИНОРОВИ'ТЬСЯ** *сов.*— җайлашу, иплашу.

**ПРИНОРОВЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. приноравливать.

**ПРИНОРОВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— к. приноравливаться.

**ПРИНОСИ'ТЬ** *несов.*— к. принести.

**ПРИНОСИ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. *разг.* к. принестись; 2. *страд.* китерелү.

**ПРИНОШЕ'НИЕ** *ср. книж.*— 1. *только ед. устар.* к. приносить; 2. *(жертва)* корбан; (*дар*) бүләк; 3. *устар. ирон.* взятка, ришвәт.

**ПРИНУДИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— мәҗбүрилек, мәҗбүри булу.

**ПРИНУДИ'ТЕЛЬНЫЙ** — мәҗбүри.

**ПРИНУ'ДИТЬ** *сов.*— мәҗбүр итү, ирексезләү.

**ПРИНУЖДА'ТЬ** *несов.*— к. принудить.

**ПРИНУЖДА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— мәҗбүр ителү, ирексезләнү.

**ПРИНУЖДЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. (*действие*) к. принудить; 2. к. принуждённость.

**ПРИНУЖДЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет — ясалмалык.

**ПРИНУЖДЁННЫЙ** — 1. мәҗбүр ителгән, көчләп эшләнгән; 2. *только полн. формы* ясалма, көчәнеп..., көчәнүле; *принуждённые манеры*—ясалма кыланышлар; *принуждённый смех* — көчәнеп (ясалма) көлү.

**ПРИНЦ** *м.*—принц (Көнбатыш Европада—король яки князь семьясы агъзасының титулы).

**ПРИНЦЕ'ССА** *ж.*— принцесса (к. принц).

**ПРИ'НЦИП** *м. книж.*— 1. принцип, нигез, асыл; *основные принципы механики* — механиканың төп принциплары; 2. закон; *принцип всемирного тяготения* — бөтен дөнья тартылу законы; 3. *(убеждение)* принцип, төп фикер, төп караш. ◇ **В принципе** — нигездә, асылда; *в принципе я согласен* — нигездә мин риза.

**ПРИНЦИПА'Л** *м.*— принципал (1. *книж.* башлык, начальник, хуҗа; 2. *муз.* органда төп регистр).

**ПРИНЦИПА'Т** *м. истор.*— принципат (борынгы Римда—Рим аристократик республикасын бетерү нәтиҗәсендә барлыкка килгән кол биләүчеләр диктатурасы).

**ПРИНЦИПИА'ЛЬНО** *нареч.*— принципиаль рәвештә, нигездә.

**ПРИНЦИПИА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— принципиальлек, принципиаль булу; принциплылык.

**ПРИНЦИПИА'ЛЬНЫЙ** *книж.*— 1. принципиаль, принципка нигезләнгән; *принципиальный вопрос* — принципиаль мәсьәлә; 2. принциплы; *принципиальный человек* — принциплы кеше; 3. принципта, принципиаль рәвештә...-ган, нигездә...-ган; *принципиальное согласие* — принципта бирелгән ризалык.

**ПРИНЮ'ХАТЬСЯ** *сов. разг.*— өйрәнү, ияләнү, күнегү (берәр төрле искә).

**ПРИНЮ'ХИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— к. принюхаться.

**ПРИНЯ'ТЬ** *сов.*— 1. алу; *принять посылку* — посылка алу; 2. тотып алу; *бросай мешок, а я снизу приму* — син капчыкны ыргыт, ә мин (аны) түбәндә тотып алырмын; 3. *офиц.* кабул итү; *принять делегацию* — делегацияне кабул итү; 4. каршылау, каршы алу, кабул итү; *меня там плохо приняли* — анда мине начар каршы алдылар; 5. эчү; *принять лекарство* — дару эчү; 6. (дип) белү, (дип) санау; *его приняли за знакомого* — аны таныш кеше дип белгәннәр; 7. *простореч.* алып китү; алу; *хозяин позвонил и велел принять остатки ужина* — хуҗа шалтыратып калган ашларны алып китәргә кушты; *прими руки прочь* — кулларыңны ал моннан; 8. *воен.* кабатлау; *принять команду* — боерыкны кабатлау. ◇ **Принять решение** — 1. карар кабул итү; 2. карарга килү. **Принять участие** — катнашу. **Принять обязательство** — өстенә бурыч итеп алу, йөкләмә алу. **Принять меры** — чара күрү. **Принять смерть** *от кого-н.*— (берәр кеше тарафыннан) үтерелү. **Принять ванну (душ)** — ваннада (душта) юыну (коену). **Принять побои** — кыйналу. **Принять муку** — җәфа чигү. **Принять в шутку его слова** — аның сүзләрен уенга алу. **Не прими это в обиду** — хәтерең калмасын, күңелеңә авыр алма. **Принять на свой счёт** — үзеңә алу, үз исәбеңә алу. **Принять за чистую монету** — чынга алу, чынга тарту, чын дип белү (уйлау). **Принять в дом** — к. дом. **Принять к сердцу** — күңелгә якын алу. **Принять участие** — катнашу. **Принять меры** — чара күрү. **Принять в штыки** *перен.*— кискен каршылык күрсәтү, сәнәккә күтәрү. **Принять присягу** — ант итү, присяга бирү. **Принять намерение** — исәпләү, исәп тоту, ниятләү. **Дело приняло хороший оборот** — эш унайга китте. **Спор принял ожесточённый характер** — бәхәс кызып китте. **Прими мой совет** — минем киңәшемне тыңла, минем киңәшемне тот. **Принять вправо** — уңга тоту, уңга каеру. **Город принял нарядный вид** — шәһәр матур төс алды.

**ПРИНЯ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. башлау, керешү,

тотыну; *приняться за работу* — эшкә керешү; 2. тамыр җибәрү, төпләнү, үсеп китү, үсә башлау; *деревцо принялось*— агач тамыр җибәргән; 3. чыгу, тулу; *оспа принялась* — чәчәк чыккан, чәчәге тулган.

**ПРИОБВЫ'КНУТЬ** *сов. простореч.*— к. привыкнуть.

**ПРИОБОДРИ'ТЬ** *сов.*— бераз дәртләндереп җибәрү, бераз рухландырып җибәрү, күңелен күтәреп җибәрү.

**ПРИОБОДРИ'ТЬСЯ** *сов.*— бераз дәртләнеп китү, бераз рухланып китү, бераз рухы күтәрелеп китү, рухы күтәрелә төшү, күңеле күтәрелеп китү.

**ПРИОБОДРЯ'ТЬ** *несов.*— к. приободрить.

**ПРИОБОДРЯ'ТЬСЯ** *несов.*— к. приободриться.

**ПРИОБРЕСТИ'** *сов.*— 1. алу, булдыру; *приобрести познания* — белем алу; 2. алу, казану; ия булу; *приобрести большое значение* — зур әһәмияткә ия булу; 3. сатып алу; *приобрести пальто* — пальто сатып алу.

**ПРИОБРЕТА'ТЕЛЬ** *м. книж.*— 1. сатып алучы; 2. байлык җыючы.

**ПРИОБРЕТА'ТЬ** *несов.*— к. приобрести.

**ПРИОБРЕТА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. алыну, булдырылу; 2. сатып алыну.

**ПРИОБРЕТЕ'НИЕ** *ср.*— 1. *только ед. (действие)* к. приобрести; 2. казаныш; *радио — важное приобретение культуры* — радио—культураның әһәмиятле казанышы; 3. *разг. (то, что куплено)* сатып алган әйбер; 4. *разг.* табыш.

**ПРИОБЩА'ТЬ** *несов.*— к. приобщить.

**ПРИОБЩА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. приобщиться; 2. *страд.* тартылу, катнаштырылу, аралаштырылу; 3. *страд.* беркетелү, теркәлү.

**ПРИОБЩИ'ТЬ** *сов.*— 1. *книж.* тарту, катнаштыру, аралаштыру; *приобщить к культуре* — культурага тарту; 2. *офиц.* теркәү, теркәп кую, беркетү, беркетеп кую; *приобщить к делу заявление* — гаризаны делога теркәү.

**ПРИОБЩИ'ТЬСЯ** *сов. книж.*— катнашу, аралашу, кушылу.

**ПРИОБЫКА'ТЬ** *несов. простореч.*— к. приобыкнуть.

**ПРИОБЫ'КНУТЬ** *сов. простореч.* — к. привыкнуть.

**ПРИОВРА'ЖЬЕ** *ср. спец.*— чокыр буе, чокыр янындагы җир, коры елга буендагы җир.

**ПРИОДЕ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. *(снабдить одеждой)* өстен-башын киендерү; 2. *(принарядить)* матур итеп киендерү, киендерү-ясандыру, яхшы кием кидерү.

**ПРИОДЕ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. *(нарядиться)* матур итеп киенү, киенү-ясану, яхшы кием кию; 2. *простореч. (приобрести одежду)* өс-башны юнәтү, өс-башны бөтәйтү.

**ПРИОЗЁРНЫЙ** — күл янындагы, күл тирәсендәге, күл буе...-ы; *приозёрный участок* — күл буе участогы.

**ПРИОРИТЕ'Т** *м. мн.* нет, *книж.*— приоритет, беренчелек (берәр нәрсәне ачуда, уйлап чыгаруда).

**ПРИОСА'НИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— к. приосаниться.

**ПРИОСА'НИТЬСЯ** *сов. разг.* — гәүдәне турайтып олысымаклану, гәүдәне турайту.

**ПРИОСМОТРЕ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— ияләшү, өйрәнү, күнегү (яңа обстановкага, кешеләргә).

**ПРИОСТАНА'ВЛИВАТЬ** *несов.*— к. приостановить.

**ПРИОСТАНА'ВЛИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. приостановиться; 2. *страд.* беразга туктатылу, туктатылып тору.

**ПРИОСТАНОВИ'ТЬ** *сов.*— беразга туктату, туктатып тору.

**ПРИОСТАНОВИ'ТЬСЯ** *сов.* — беразга тукталу, тукталып калу.

**ПРИОТВОРИ'ТЬ** *сов.*— бераз ачу, ача төшү, бераз ача төшеп кую.

**ПРИОТВОРИ'ТЬСЯ** *сов.*— бераз ачылу, ачыла төшү.

**ПРИОТВОРЯ'ТЬ** *несов*— к. приотворить.

**ПРИОТВОРЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— бераз ачылу, ачыла төшү, бераз ачылып куелу.

**ПРИОТКРЫВА'ТЬ** *несов.*—к. приоткрыть.

**ПРИОТКРЫВА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. приоткрыться; 2. *страд.* бераз ачылу, ачыла төшү.

**ПРИОТКРЫ'ТЬ** *сов.* — бераз ачу, ача төшү, бераз ачып кую; *приоткрыть дверь*— ишекне бераз ачу.

**ПРИОТКРЫ'ТЬСЯ** *сов.* — бераз ачылу, ачыла төшү, бераз ачылу.

**ПРИОТЛЕ'ЧЬ** *сов. безл. разг.*: **приотлегло от сердца** — күңелем бераз тынычланып китте.

**ПРИОХО'ТИТЬ** *сов. разг.*— теләк тудыру, дәрт кузгату, һәвәсләндерү, кызыктыру; өйрәтеп җибәрү, күнектерү.

**ПРИОХО'ТИТЬСЯ** *сов. разг.*— күнегеп китү, өйрәнеп китү; дәрте кузгалу, кызыгу, һәвәсләнү.

**ПРИОХО'ЧИВАТЬ** *несов. разг.*— к. приохотить.

**ПРИОХО'ЧИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. приохотиться.

**ПРИПАДА'ТЬ** *несов.*— 1. к. припасть; 2. *разг.* аксаклау, аз гына аксау. ◇ **Припадать к ногам (или к стопам)** *книж. ритор. устар.* — аягына егылу.

**ПРИПА'ДОК** *м.*— үз чире тоту, зыяндаш авыруы, өянәк.

**ПРИПА'ДОЧНЫЙ** — үз чирле, зыяндаш авырулы.

**ПРИПА'ИВАТЬ** *несов.*— к. припаять.

**ПРИПА'ИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. припаяться; 2. *страд.* паять ителү, кургаш белән ябыштырылу, кургаш коеп ябыштырылу.

**ПРИПА'ЛЗЫВАТЬ** *несов.* — к. приползать.

**ПРИПА'ЛИВАТЬ** *несов. разг.*— к. припалить.

**ПРИПА'ЛИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— 1. көйдерелү, өтелү, көйдереп алыну, өтеп алыну; 2. яндырып бетерелү, ягып бетерелү.

**ПРИПАЛИ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. яндыру, яндырып алу, көйдерү, көйдереп алу; өтү, өтеп алу; *усы припалил* — мыекларын көйдергән; 2. *обл.* яндырып бетерү, ягып бетерү; *все дрова припалили* — барлык утынны ягып бетергәннәр.

**ПРИПА'РИВАТЬ** *несов. разг.*— к. припарить.

**ПРИПА'РИТЬ** *сов. разг.*— парлау, пешекләү.

**ПРИПА'РКА** *ж.* — 1. *только ед. (действие)* к. припарить; 2. припарка (авырткан җиргә кайнарлатып куела торган сыек яки камырсыман дару).

**ПРИПА'РХИВАТЬ** *несов. разг.*— к. припорхнуть.

**ПРИПАСА'ТЬ** *несов. разг.*— к. припасти.

**ПРИПАСА'ТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— алдан хәзерләнү, хәзерләнеп куелу.

**ПРИПАСОВА'ТЬ** *сов. тех.*— бер-беренә туры китереп ныгыту, туры китереп беркетү.

**ПРИПАСО'ВЫВАТЬ** *несов. тех.*— к. припасовать.

**ПРИПАСО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд. тех.*— бер-беренә туры китереп ныгытылу.

**ПРИПАСТИ'** *сов. разг.*— алдан хәзерләү, хәзерләп кую.

**ПРИПА'СТЬ** *сов.*— 1. яту, сарылу; *собака припала к земле* — эт җиргә ятты; 2. *разг. устар.* кинәт барлыкка килү, кинәт туу, кинәт...-ып китү; *припала страсть к чтению* — кинәт укуга һәвәсләнеп киттем.

**ПРИПА'СЫ** *мн.*— 1. *(провизия)* азык, азык-төлек; 2. кирәк-яраклар; *рыболовные припасы* — балык тоту кирәк-яраклары; 3. *воен.* припаслар; *боевые припасы* — сугыш припаслары (снарядлар, патроннар һ. б.).

**ПРИПАХА'ТЬ** *сов. обл.*— 1. кереп сөрү, өстәп сөрү; 2. *(вспахать всё)* сөреп чыгу, сөреп бетерү.

**ПРИПА'ХИВАТЬ** I. *несов. разг.*— 1. бераз ... исе килү (килеп тору); *чай припахивает мылом* — чәйдән бераз сабын исе килеп тора; 2. ис керә башлау, исләнә башлау, сасый башлау; *рыба уже припахивает* — балыкка бераз ис керә башлаган инде.

**ПРИПА'ХИВАТЬ** II *несов. обл.*— к. припахать.

**ПРИПАЯ'ТЬ** *сов.*— паять итү, кургаш коеп ябыштыру, кургаш белән ябыштыру.

**ПРИПАЯ'ТЬСЯ** *сов.*— (эреп) ябышу; паять ителү; *ручка к кастрюльке плохо припаялась* — кастрюльнең сабы (тоткасы) начар паять ителгән.

**ПРИПЕ'В** *м.*— кушымта (җырда).

**ПРИПЕВА'ТЬ** *несов.* — 1. *(исполнять припев)* кушымтаны җырлау; 2. *разг.* җырлау, көйләү; *работает, припевая* — җырлый-җырлый эшли.

**ПРИПЕВА'ЮЧИ** *нареч. разг.*: **жить припеваючи** — рәхәт яшәү, мул яшәү, иркен яшәү, ал да гөл яшәү.

**ПРИПЁК** *м. мн.* нет — 1. припёк (тотылган онга караганда пешкән икмәкнең авырлык ягыннан артуы); 2. *разг.* кояш кызуы; кояш кыздыра торган урын; *люблю сидеть на припёке* — кояш кызуында утырырга яратам.

**ПРИПЁКА** *ж. мн.* нет, *обл.*— к. припёк. ◇ **С боку припёка** — 1. *(о ком-н.)* кирәкле кешер яфрагы (кирәксез кеше турында); 2. *(о чем-н.)* тик торганда, искәрмәстән, токтымалга.

**ПРИПЕКА'ТЬ** *несов.*— 1. кыздыру, яндыру; *солнце припекает* — кояш кыздыра; 2. к. припечь.

**ПРИПЕКА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. припечься; 2. *страд.* кыздырылу, яндырылу, көйдерелү.

**ПРИПЕРЕ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. *простореч.* кысу, китереп (илтеп) кысу; *толпа нас припёрла к забору* — халык төркеме безне коймага китереп кысты; 2. терәү, терәтү, терәтеп кую; *припереть ворота бревном* — капканы бүрәнә белән терәтеп кую; 3. *простореч.* яба төшү, аз гына ябу, кысып кую; *припереть дверь* — ишекне яба төшү, ишекне кысып кую; 4. *простореч. вульг.* килү; *припёр к нам и сидит* — безгә килгән дә утыра; 5. *простореч. вульг.* китерү, күтәреп китерү; *припереть мешок* — капчыкны күтәреп китерү. ◇ **Припереть к стене** *разг.*— ике аягын бер итеккә (бер кунычка) тыгу, котылгысыз хәлгә төшерү.

**ПРИПЕРЕ'ТЬСЯ** *сов. простореч. вульг.*— к. припереть 4.

**ПРИПЕ'РЧИВАТЬ** *несов. разг.*— к. приперчить.

**ПРИПЕ'РЧИТЬ** *сов. разг.*— бераз борычлау, бераз борыч сибү.

**ПРИПЕЧА'ТАТЬ** *сов.*— 1. *(дополнительно напечатать)* өстәп бастыру, өстәмә рәвештә бастыру; 2. *разг. (поставить печать)* печать басу; 3. *разг.* печатьләп кую; *припечатать сургучом* — сургуч белән печатьләп кую; 4. *перен. (ударить)* чәпәү, тондыру, кундыру (сугу мәгънәсендә).

**ПРИПЕЧА'ТЫВАТЬ** *несов.*— к. припечатать.

**ПРИПЕЧА'ТЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. өстәп бастырылу, өстәмә рәвештә бастырылу; 2. печать басылу; 3. *разг.* печатьләп куелу.

**ПРИПЕ'ЧЬ** *сов.*— 1. *разг.* *(сильно поджарить)* (артык, нык) кыздыру; көйдерү; 2. *обл.* пешереп өстәү; 3. *разг.* (бер-беренә) ябыштырып пешерү.

**ПРИПЕ'ЧЬСЯ** *сов.*— 1. *разг.* пешкәч арту, припёк бирү; *два кило припеклось* — пешкәч ике килога артты, ике кило припёк бирде; 2. *разг.* ябышып пешү.

**ПРИПИРА'ТЬ** *несов. разг.*— к. припереть.

**ПРИПИРА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. *простореч. вульг.* к. припереть 4; 2. *страд.* терәтеп куелу.

**ПРИПИСА'ТЬ** *сов.*— 1. өстәп язу, өстәмә рәвештә язу; *приписать новую главу к книге* — китапка яңа бүлек өстәп язу; 2. *офиц.* язу, теркәү, язып кую, теркәп кую; *приписать к призывному участку* — призыв участогына теркәп кую; 3. ...-дан күрү, сылтау, кайтарып калдыру; *чему вы приписываете вашу болезнь?* — сез авыруыгызны нәрсәдән күрәсез?

**ПРИПИСА'ТЬСЯ** *сов. офиц.*— язылу, теркәлү.

**ПРИПИ'СКА** *ж.*—1. *только ед.* (*действие*) к. приписать 1, 2; 2. өстәп язылган язу (язма).

**ПРИПИСНО'Й** *офиц.*— теркәлгән, беркетелгән.

**ПРИПИ'СЫВАТЬ** *несов.*— к. приписать.

**ПРИПИ'СЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. *офиц.* к. приписаться; 2. *страд.* өстәп язылу, өстәмә рәвештә язылу; язып куелу, теркәп куелу. ◇ **Мне приписываются всякие небылицы** — миңа төрле юк-бар нәрсәләр тагалар.

**ПРИПИ'ТЬ** *сов. простореч.*— эчеп бетерү.

**ПРИПИ'ХИВАТЬ** *несов. разг.*— к. припихнуть.

**ПРИПИХНУ'ТЬ** *сов. разг.*— этеп кую, этеп күчерү, этеп якынайту; *припихнуть корзину к стене* — кәрзинне стена янына этеп кую.

**ПРИПЛА'ТА** *ж. мн.* нет— 1. (*действие*) к. приплатить; 2. өстәмә түләнгән акча.

**ПРИПЛАТИ'ТЬ** *сов.*— өстәп түләү, өстәмә рәвештә түләү.

**ПРИПЛАТИ'ТЬСЯ** *сов. устар.*— к. поплатиться.

**ПРИПЛА'ЧИВАТЬ** *несов.*— к. приплатить.

**ПРИПЛА'ЧИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. *устар.* к. приплатиться; 2. *страд.* өстәп түләнү, өстәмә рәвештә түләнү.

**ПРИПЛЕСНУ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. (*выкинуть на берег*) ярга чыгарып ташлау (дулкын белән); 2. бәреп керү; *волна приплеснула в лодку* — дулкын көймәгә бәреп керде.

**ПРИПЛЕСТИ'** *сов. простореч.*— 1. кушып үрү; *приплести вторую ленту в косу* — чәчкә икенче тасманы кушып үрү; 2. *перен. разг. фам.* арага кыстыру, арага кыстырып әйтү, арага китереп кыстыру, кертеп чуалту; *прошу посмотреть, какие пули отливает! и старика отца приплёл!* (Гоголь)— рәхим итеп карагыз инде, ничек борчак ата! житмәсә тагын әтисе картны да арага китереп кыстыра!

**ПРИПЛЕСТИ'СЬ** *сов. разг. фам.*— көчхәл белән килеп (барып, кайтып) житү.

**ПРИПЛЕТА'ТЬ** *несов.*— к. приплести.

**ПРИПЛЕТА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— кушып үрелү.

**ПРИПЛО'Д** *м. мн.* нет — үрчем (мал-туарның).

**ПРИПЛЫВА'ТЬ** *несов.*— к. приплыть.

**ПРИПЛЫ'ТЬ** *сов.*— 1. йөзеп килү, йөзеп килеп житү; 2. утырып килү (пароходка, көймәгә һ. б.); *приплыл на лодке* — көймәгә утырып килдем.

**ПРИПЛЮ'СНУТЫЙ** — изелгән, яньчелгән, ямьшәйгән; яньчек, җәлпәк.

**ПРИПЛЮ'СНУТЬ** *сов.*— яньчү, җәлпәйтү; изү, ямьшәйтү.

**ПРИПЛЮСОВА'ТЬ** *сов. разг.* — өстәү, өстәп кушу.

**ПРИПЛЮСО'ВЫВАТЬ** *несов.*— к. приплюсовать.

**ПРИПЛЮСО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— өстәлү, кушылу.

**ПРИПЛЮ'ЩИВАТЬ** *несов.*— к. приплюснуть.

**ПРИПЛЮ'ЩИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— яньчелү, җәлпәйтелү, ямьшәйтелү.

**ПРИПЛЯ'СЫВАТЬ** *несов.*— биештергәләп тору, биештергәләү.

**ПРИПОДНИМА'ТЬ** *несов.* — к. приподнять.

**ПРИПОДНИМА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. приподняться; 2. *страд.* бераз күтәрелү, аз гына күтәрелү.

**ПРИПО'ДНЯТОСТЬ** *ж. мн.* нет—күтәренкелек.

**ПРИПО'ДНЯТЫЙ**—1. бераз күтәрелгән, бераз күтәрелә төшкән; 2. *перен.* күтәренке; *приподнятое настроение* — күтәренке рух, күтәренке настроение.

**ПРИПОДНЯ'ТЬ** *сов.*— бераз күтәрү, аз гына күтәрү, күтәрә төшү.

**ПРИПОДНЯ'ТЬСЯ** *сов.*— аз гына күтәрелә төшү, бераз күтәрелә төшү.

**ПРИПОДЫМА'ТЬ** *несов. простореч.*— к. приподнять.

**ПРИПОДЫМА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— к. приподниматься.

**ПРИПО'Й** *м. мн.* нет, *тех.*— припой (паять иткәндә кулланыла торган эретмә).

**ПРИПОЛЗА'ТЬ** *несов.*— шуышып (үрмәләп, сөйрәлеп) килү, шуышып (үрмәләп, сөйрәлеп) килеп житү.

**ПРИПОЛЗТИ'** *сов.*— к. приползать.

**ПРИПО'ЛЮСНЫЙ** — полюс янындагы, полюс тирәсендәге, полюска якын; *приполюсный район* — полюска якын район.

**ПРИПОЛЯ'РНЫЙ** — поляр түгәрәге тирәсендәге, поляр түгәрәге янындагы; *приполярные районы* — поляр түгәрәге тирәсендәге районнар.

**ПРИПОМИНА'ТЬ** *несов.*— хәтерләү, искә төшерү.

**ПРИПОМИНА'ТЬСЯ** *несов.*— к. припомниться.

**ПРИПО'МНИТЬ** *сов.*— 1. искә төшерү, хәтергә төшерү; *припомнить старого товарища* — иске дусны искә төшерү; 2. *перен. разг.* искә төшерү; *погоди, я тебе это припомню!*— тукта әле, мин моны синең исеңә төшерермен!

**ПРИПО'МНИТЬСЯ** *сов.*— искә төшү, хәтергә төшү.

**ПРИПОРОШИ'ТЬ** *сов. разг.*— аз гына каплау; *землю припорошило снегом* — жир өстен аз гына кар каплаган.

**ПРИПОРХНУ'ТЬ** *сов. разг.*—(очып) килеп куну; очып китү.

**ПРИПРА'ВА** *ж.*— приправа, аш тәмләткеч.

**ПРИПРА'ВИТЬ** *сов.*— 1. ...салу, ...салып тәмләтү; *приправить борщ сметаной* — борщка каймак салу; 2. *перен. разг.* кыстырып (кушып) сөйләү, матурлау, бизәү; *приправить свою речь остротами* — речена тапкыр сүзләр кыстырып (кушып) сөйләү, речене тапкыр сүзләр белән бизәү.

**ПРИПРАВЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. приправить.

**ПРИПРА'ШИВАТЬ** *несов. разг.*— к. припросить.

**ПРИПРОСИ'ТЬ** *сов. разг.*— өстәүне сорау, өстәү бирүне сорау, өстәмә итеп сорап алу.

**ПРИПРЫ'ГАТЬ** *сов. разг.*— сикерә-сикерә килеп җитү, сикергәләп килеп җитү.

**ПРИПРЫ'ГИВАТЬ** *несов.*— 1. к. припрыгнуть, припрыгать; 2. сикергәләү.

**ПРИПРЫ'ГНУТЬ** *сов. разг.*— сикереп килеп җитү.

**ПРИПРЯГА'ТЬ** *несов.*— к. припрячь.

**ПРИПРЯГА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— өстәп җигелү, янга җигелү, прәшкәгә җигелү.

**ПРИХВАТИ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. (үзең белән) алу, (үзең белән) алып китү; *прихватить вещи* — әйберләрне үзең белән алу; 2. үзең белән алу (алып китү), ияртү; *прихватить детей* — балаларны үзең белән алу, балаларны ияртү; 3. *фам.* алу; *надо бы денег прихватить в долг* — бурычка акча алырга кирәк иде; 4. кирәгеннән тыш ... -ып алу; *кроил и прихватил лишку* — кискәндә кирәгеннән тыш уеп (кисеп) алган; 5. бәйләп кую, эләктереп бәйләп кую; *прихватить верёвкой вещи на возу* — йөктәге әйберләрне бау белән эләктереп бәйләп кую; 6. *фам. (приврать)* сөйләгәндә арттырып жибәрү, ялган катыштырып сөйләү; 7. *безл. просторечи. (внезапно заболеть)* кинәт авырып китү. ◇ **Мороз прихватил цветы** — чәчәкләргә кырау тигән, чәчәкләрне салкын суккан.

**ПРИХВА'ТЫВАТЬ** *несов. разг.*— к. прихватить.

**ПРИХВА'ТЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. үзең белән алыну; 2. эләктереп бәйләп куелу.

**ПРИХВОРНУ'ТЬ** *сов.*— авырып китү, бераз авырып китү; бераз авырып алу.

**ПРИ'ХВОСТЕНЬ** *м. разг. бран.*— куштан, иярчен, койрык (ялагай).

**ПРИХЛЕБА'ЛА** *м.* и *ж. просторечи. презрит.*— к. прихлебатель.

**ПРИХЛЕБА'ТЕЛЬ** *м. разг. презрит.*— әрәм тамак, тәлинкә ялаучы.

**ПРИХЛЕБА'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет, *разг. презрит.*— әрәм тамаклык.

**ПРИХЛЕБНУ'ТЬ** *сов.*—эчеп кую.

**ПРИХЛЁБЫВАТЬ** *несов.* — эчеп-эчеп кую, аз-азлап эчү; *прихлёбывать чай*—чәй эчеп-эчеп кую.

**ПРИХЛЕСНУ'ТЬ** или **ПРИХЛЕСТНУ'ТЬ** *сов. разг.*—китереп бәрү, кагу; *сильной волной рыбу прихлеснуло к берегу* — көчле дулкын балыкны ярга китереп бәрде.

**ПРИХЛЁСТЫВАТЬ** *несов. разг.*— чыбыркы белән суккалау.

**ПРИХЛО'ПНУТЬ** *сов. разг.*— 1. шап итеп ябу, шап итеп ябып кую; *прихлопнуть дверь* — ишекне шап итеп ябу; 2. кыстыру, эләктерү; *прихлопнуть палец* — бармакны кыстыру; 3. *просторечи. (убить)* үтерү; 4. *перен. фам.* ябу, тыю, туктату; *царская цензура прихлопнула газету* — патша цензурасы газетаны япкан.

**ПРИХЛО'ПЫВАТЬ** *несов. разг.*— 1. к. прихлопнуть; 2. кул чәбәкләү; *молодёжь прихлопывала в ладоши* —яшьләр кулларын чәбәклиләр иде.

**ПРИХЛЫ'НУТЬ** *сов.*— 1. шаулап агып килү, ташып килү, килеп бәрелү; *прихлынули волны* — дулкыннар килеп бәрелде; 2. *перен.* ябырылып килү, ябырылып килеп чыгу; *прихлынула толпа* — халык төркеме

ябырылып килеп чыкты; 3. *перен.* чолгап алу; *прихлынули радостные чувства* — шатлыклы хисләр чолгап алды.

**ПРИХО'Д** I *м* — 1. *только ед. (действие)* к. прийти; 2. *только ед.* приход, керем; *записать на приход* — керемгә язып кую.

**ПРИХО'Д** II *м. устар.* — приход, мәхәллә. ◇ **Каков поп, таков и приход** — мулласына күрә мәхәлләсе, көтүчесе нинди, көтүе дә шундый.

**ПРИХОДИ'ТЬ** *несов.* — к. прийти.

**ПРИХОДИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. прийтись; 2. туры килү, булу; *она мне приходится тёткой* — ул миңа апа була.

**ПРИХО'ДНЫЙ** *спец.* — приход...-ы, приходлар...-ы, керем...-ы, керемнәр....ы; *приходная ведомость* — керемнәр ведомосте.

**ПРИХО'ДОВАТЬ** *несов бухг.* — керемгә язу.

**ПРИХО'ДО-РАСХО'ДНЫЙ** *спец.* — керемнәр һәм чыгымнар языла торган, приходлар һәм расходлар языла торган; *приходо-расходная ведомость* — керемнәр һәм чыгымнар языла торган ведомость.

**ПРИХОДЯ'ЩИЙ** — 1. килүче, килә торган; *мысли, приходящие в голову* — башка килә торган фикерләр; 2. килеп йөри торган, килеп йөрүче.

**ПРИХОЖА'НИН** *м. устар.* — приход кешесе, мәхәллә кешесе.

**ПРИХ'ОЖАЯ** *ж.* — алгы бүлмә (өс киемнәрен салып калдыра торган бүлмә); *раздеться в прихожей* — алгы бүлмәдә киемнәрне салу (чишенү).

**ПРИХОРА'ШИВАТЬ** *несов. разг.* — матурлау, кәязләндерү, купшыландыру.

**ПРИХОРА'ШИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — матурлану, бизәнү-ясану, кәязләнү, купшылану.

**ПРИХОТЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн. нет* — талымлылык, нәфеслелек, талымчанлык, таләпчәнлек.

**ПРИХОТЛИ'ВЫЙ** — 1. талымчан, нәфесле, нәзберек, талымлы, капризлы; *прихотливый человек* — талымчан кеше; 2. бормалы-сырмалы, эфәләм төрле; *прихотливый орнамент* — бормалы-сырмалы орнамент.

**ПРИ'ХОТЬ** *ж.* — көйсезлек, капризлылык, капризлы теләк, талымлылык, нәзбереклек; нәфес.

**ПРИХРА'МЫВАТЬ** *несов.* — бераз (аз гына) аксау, бераз (аз гына) аксый төшү, аксаклау.

**ПРИЦВЕ'ТНИК** *м. бот.* — чәчәк яны яфрак, чәчәк төбе.

**ПРИЦЕДИ'ТЬ** *сов. разг.* — сөзеп өстәү.

**ПРИЦЕ'ЖИВАТЬ** *несов. разг.* — к. прицедить.

**ПРИЦЕ'ЖИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — өстәп сөзелү.

**ПРИЦЕ'Л** *м.* — 1. прицел, төзәгеч; *рамка прицела* — прицел рамкасы; 2. төзәү, төбәү; *линия прицела* — төзәү сызыгы. ◇ **Взять (или брать) на прицел** — 1. прицелга алу; 2. *перен.* тәнкыйть уты астына алу, прицелга алу.

**ПРИЦЕ'ЛИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. прицелить.

**ПРИЦЕ'ЛИВАТЬСЯ** *несов.* — к. прицелиться.

**ПРИЦЕ'ЛИТЬ** *сов. простореч.* — төзәү, төбәү.

**ПРИЦЕ'ЛИТЬСЯ** *сов.* — 1. *(навести на цель)* төзәү, төбәү; 2. *перен. разг. фам.* алырга хәзерләнү, алырга хәзерләнеп тору, тотып алырга әзерләнү.

**ПРИЦЕ'ЛЬНЫЙ** *воен.* — прицел...-ы, төзәү...-ы, төбәү...-ы; *прицельная рамка* — прицел рамкасы.

**ПРИЦЕ'НИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. прицениться.

**ПРИЦЕНИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — бәясен (хакын) сорау, бәясен (хакын) сорап белү.

**ПРИЦЕ'П** *м.* — 1. к. прицепка 1, 2, 3; 2. *собир.* тагылма машиналар, тагылма инвентарь.

**ПРИЦЕПИ'ТЬ** *сов.* — 1. эләктерү, тагу; *прицепить вагон* — вагонны тагу; 2. *разг.* кадау, кадап кую; *прицепить бант* — бант кадап кую.

**ПРИЦЕПИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. ябышу; *зелёные нити моху прицепились к его платью* — аның күлмәгенә яшел мүк җепселләре ябышкан; 2. к. пристать 2, 3, 4; 3. *перен. разг. фам.* бәйләнү; *прицепиться к слову* — сүзгә бәйләнү.

**ПРИЦЕ'ПКА** *ж.* — 1. *только ед. разг. спец. (действие)* к. прицепить; 2. прицеп, тагылма; 3. *простореч.* ыргак, элгеч; 4. *перен. разг. фам.* к. придирка.

**ПРИЦЕПЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. прицепить.

**ПРИЦЕПЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. прицепиться; 2. *страд.* эләктерелү, тагылу; кадалу, кадап куелу.

**ПРИЦЕПНО'Й** — тагылма ...; *прицепной вагон* — тагылма вагон.

**ПРИЦЕ'ПЩИК** *м.* — прицепщик (тагылма инвентарьда эшләүче).

**ПРИЦЫ'КНУТЬ** *сов. простореч. фам.* — кычкырып кую, җикеренеп кую.

**ПРИЧА'Л** *м.* — 1. *только ед. (действие)* к. причалить 1, 2; 2. причал (а. дирижабльне, судноны бәйләп, эләктереп куя торган аркан; б. судно, дирижабль туктый торган урын).

**ПРИЧА'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. причалить.

**ПРИЧА'ЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — китереп бәйләп куелу.

**ПРИЧА'ЛИТЬ** *сов.* — 1. китереп бәйләп кую; *причалить барку к берегу* — барканы яр буена китереп бәйләп кую; 2. килеп туктау; *мы причалили к пристани* — без пристаньга килеп туктадык; 3. *перен. разг. (примкнуть на чью-л. сторону)* ... ягын алу,... ягына күчү.

**ПРИЧА'ЛЬНЫЙ** — причал...-ы, бәйләп куя торган; *причальная мачта для дирижаблей* — дирижабльләрне бәйләп куя торган мачта.

**ПРИЧА'СТИЕ** I *ср. грам.* — сыйфат фигыль.

**ПРИЧА'СТИЕ** II *ср. церк.* — 1. причастие

(христианнарда: просвира кисәге салынган аракы); 2. к. причащение.

**ПРИЧА'СТИЕ** III *ср. мн.* нет, *книж. устар.*— к. причастность.

**ПРИЧАСТИ'ТЬ** *сов. книж. ритор. устар.*— к. приобщить 1.

**ПРИЧАСТИ'ТЬСЯ** *сов.*—1. *церк.* чиркәүдә просвира салынган кызыл аракы эчеп гөнаһлардан арыну; 2. *книж. ритор. устар.* к. приобщиться.

**ПРИЧА'СТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— катнашу, катнашы булу, катнашы барлык, мөнәсәбәте булу.

**ПРИЧА'СТНЫЙ** I *грам.*— сыйфат фигыль...-ы; *причастная форма* — сыйфат фигыль формасы.

**ПРИЧА'СТНЫЙ** II *книж.*— катнашкан, катнашы булган, катнашы бар..., мөнәсәбәте булган.

**ПРИЧАЩА'ТЬ** *несов. книж. ритор.*— к. причастить.

**ПРИЧАЩА'ТЬСЯ** *несов.*— к. причаститься 1.

**ПРИЧАЩЕ'НИЕ** *ср. церк.* — причащение (чиркәүдә просвира салынган аракы эчеп гөнаһлардан арыну йоласы).

**ПРИЧЁМ** *союз* — өстәвенә, өстәвенә тагы, шуның белән бергә.

**ПРИЧЕРТИ'ТЬ** *сов.*— өстәп сызу, өстәмә рәвештә сызу (чертёж турында).

**ПРИЧЕ'РЧИВАТЬ** *несов.*— к. причертить.

**ПРИЧЕСА'ТЬ** *сов.*— тарау, тарап кую.

**ПРИЧЕСА'ТЬСЯ** *сов.* — чәчне тарау; *я причесался* — мин чәчемне тарадым.

**ПРИЧЁСКА** *ж.*— 1. *только ед. (действие)* к. причесать, причесаться; 2. причёска.

**ПРИЧЕ'СТЬ** *сов.*— 1. *простореч.* к. присчитать; 2. *устар.* к. причислить 3.

**ПРИЧЁСЫВАТЬ** *несов.*— к. причесать.

**ПРИЧЁСЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. причесаться; 2. *страд.* таралу, тарап куелу.

**ПРИ'ЧЕТ** I, **ПРИЧЁТ** I *м. обл. лит.*— к. причитание.

**ПРИ'ЧЕТ** II, **ПРИЧЁТ** II *м. церк.*— к. причт.

**ПРИЧИ'НА** *ж.*— 1. сәбәп, сылтау; *без всякой причины* — һичбер сәбәпсез; 2. *филос.* сәбәп.

**ПРИЧИНДА'ЛЫ** *ед.* нет, *простореч. фам. шутл.*— кирәк-яраклар.

**ПРИЧИНИ'ТЬ** *сов. книж.*— китерү, ясау, күрсәтү; *причинить убыток* — зарар китерү. ◇ **Причинить беспокойство** — тынычсызлау, борчу, мазасызлау, тынычсызлык тудыру.

**ПРИЧИ'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *филос.*— сәбәплелек.

**ПРИЧИ'ННЫЙ** — 1. *филос.* сәбәплелек...-ы; *причинная связь* — сәбәплелек бәйләнеше; 2. *простореч. (замешанный)* катнашы булган, катнашы бар.

**ПРИЧИНЯ'ТЬ** *несов. книж.*— к. причинить.

**ПРИЧИНЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.*— китерелү, ясалу; күрсәтелү.

**ПРИЧИ'СЛИТЬ** *сов.*— 1. *разг.* кушып исәпләү, өстәп исәпләү, кертеп исәпләү; *причисли эту сумму к доходу* — бу сумаңы доходка кертеп исәплә; 2. *офиц.* (хезмәткә) билгеләү; *причислить к воинской службе* — гаскәри хезмәткә билгеләү; 3. ...рәтенә кертү, дип тану, дип исәпләү, дип санау; *причислить писателя к классикам* — язучыны классиклар рәтенә кертү.

**ПРИЧИСЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. причислить.

**ПРИЧИСЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. кертеп исәпләнү, кушып исәпләнү, өстәп исәпләнү; 2. (хезмәткә) билгеләнү; 3. рәтенә кертелү, танылу.

**ПРИЧИТА'ЛЬЩИЦА** *ж. обл.*— ялланып елаучы (мәет озатканда).

**ПРИЧИТА'НИЕ** *ср.*— к. причитать.

**ПРИЧИТА'ТЬ** *несов.*— такмаклап елау (мәет озатканда, кыз озатканда һ. б.).

**ПРИЧИТА'ТЬСЯ** *несов. офиц. канц.*— туры килү, тиеш булу, тию; *ему причитается сто рублей* — аңа йөз сум тия.

**ПРИЧИ'ТЫВАТЬ** *несов. простореч.*— к. присчитать.

**ПРИЧМО'КИВАТЬ** *несов. разг.*— авыз чапылдату, авыз чапылдатып тору.

**ПРИЧМО'КНУТЬ** *сов.*— авыз чапылдатып кую.

**ПРИЧТ** *м.*— 1. *церк.* руханилар (бер чиркәүнең руханилары); 2. *перен. шутл.* катнашучылар, катнашучылар төркеме.

**ПРИЧУ'ДА** *ж.*— каприз, сәер кыланыш, холыксызлык.

**ПРИЧУ'ДИТЬСЯ** *сов. разг.*— күзгә күренү; *причудилось от страха* — куркуыннан күзенә күренгән.

**ПРИЧУ'ДЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. хикмәтлелек, әкәмәтлелек; 2. көйсезлек, холыксызлык.

**ПРИЧУ'ДЛИВЫЙ** — 1. *(замысловатый)* хикмәтле, әкәмәт, әфәләм төрле; 2. *разг. (капризный)* көйсез, холыксыз, сәер.

**ПРИЧУ'ДНИК** *м.*, **ПРИЧУ'ДНИЦА** *ж. разг.*— сәер кеше, холыксыз кеше.

**ПРИЧУ'ДНИЧАТЬ** *несов. разг.*— көйсезләнү, холыксызлану, сәер кылану.

**ПРИША'БРИВАТЬ** *несов. тех.*— к. пришабрить.

**ПРИША'БРИВАТЬСЯ** *несов. страд. тех.*— игәү белән тигезләп җайлаштырылу (иплаштерелү, туры китерелү).

**ПРИША'БРИТЬ** *сов. тех.*— игәү белән тигезләп җайлаштыру (иплаштерү, туры китерү).

**ПРИШАГА'ТЬ** *сов. простореч. шутл.*— җәяү килү, җәяүләп килү, тәпи-тәпи килү.

**ПРИ'ШВА** *ж. спец.* — аю башы (туку станогында буй җепне ныгытып кую һәм сугылган киндерне урау өчен кечкенә вал).

**ПРИШВАРТОВА'ТЬ** *сов. мор. ав.*— китереп бәйләп кую (пароход, дирижабль турында).

**ПРИШВАРТОВА'ТЬСЯ** *сов. мор. ав.*— причалга килеп туктау (пароход, дирижабль турында).

**ПРИШВАРТО'ВЫВАТЬ** *несов. мор. ав.*— к. пришвартовать.

**ПРИШВАРТО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. мор. ав.*— 1. к. пришвартоваться; 2. *страд.* бәйләп куелу.

**ПРИШЕ'ЛЕЦ** *м. книж.*— 1. читтән кил-

тән кеше, килмешәк; 2. *перен.* (*о чём-н. чужеродном*) ят бер нәрсә, чит бер нәрсә.

**ПРИШЕПЁТЫВАТЬ** *несов. разг.*— бераз шышылдап сөйләү (с, з авазларын ш, ж белән алмаштырып сөйләү).

**ПРИШЁПТЫВАТЬ** *несов.*— пышылдау, пышылдап сөйләү, пышылдап-пышылдап кую.

**ПРИШЕ'СТВИЕ** *ср. устар.*— килү, килеп чыгу. ◇ **Второе пришествие** *разг. шутл.*— кыямәт, ахыр заман (һичбер вакытта булмаячак вакыйга турында әйтелә).

**ПРИШИБА'ТЬ** *несов. просторен.*— к. пришибить 1, 2.

**ПРИШИБИ'ТЬ** *сов.*— 1. *просторен.* (*повредить ударом*) бәреп (бәрдереп) имгәтү, сугып (суктырып) имгәтү; 2. *просторен.* (*убить*) сугып үтерү; 3. *перен. разг. фам.* күңелне төшерү, рухны төшерү, изү; *неприятное известие совсем пришибло его* — күңелсез хәбәр бөтенләй аның рухын төшерде.

**ПРИШИ'БЛЕННЫЙ**— 1. бәреп (бәрдереп) имгәтелгән, сугып (суктырып) имгәтелгән; 2. сугып үтерелгән; 3. *перен. разг. фам.* төшенке рухлы, рухсыз, изелгән; *пришибленный человек* — төшенке рухлы кеше. ◇ **Пришибленное настроение** *разг. фам.*— төшенке настроение.

**ПРИШИВА'ТЬ** *несов.*— к. пришить.

**ПРИШИВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. тегелү, тегеп куелу; 2. кадаклап беркетеп куелу, кадаклап куелу.

**ПРИШИВНО'Й** — тегеп куелган; *пришивной воротник* — тегеп куелган яка.

**ПРИШИ'ТЬ** *сов.*— 1. тегү, тегеп кую; тоту; *пришить кружева к юбке* — юбкага челтәр тоту; 2. *плот.* кадаклап кую, кадаклап беркетеп кую, кадаклап тоташтырып кую; *пришить доски* — такталарны кадаклап беркетеп кую; 3. *просторен. фам.* (*впутать*) катнаштыру, бутау; 4. *просторен. фам.* юкка гаепләү, (нигезсез) гаепләү; *пришить мещанство* — мещанлыкта юкка гаепләү; 5. *вор. арго* (*убить*) дөмектерү.

**ПРИШКО'ЛЬНЫЙ** — мәктәп янындагы; мәктәп яны...-ы; *пришкольный участок* — мәктәп янындагы участок.

**ПРИШЛЁПАТЬ** *сов. просторен. фам.*— шапылдап атлап килеп җитү, лап-лап атлап килеп җитү.

**ПРИШЛЁПНУТЬ** *сов. разг.*— 1. (*шлёпнув, придавить*) чалт итеп сугып изү, шап иттереп сугып изү; 2. *фам.* басу, кую; *пришлёпнуть печать* — печать басу; 3. *фам.* җиңелчә генә сугу; *пришлёпнуть по плечу* — күлбашына җиңелчә генә сугу.

**ПРИШЛЁПЫВАТЬ** *несов. разг.*— к. пришлёпнуть.

**ПРИШЛИФОВА'ТЬ** *сов. спец.*— шомартып җайлаштыру (шома нәрсәгә бик тыгыз тиеп торырлык итеп ышкып шомарту).

**ПРИШЛИФО'ВЫВАТЬ** *несов. спец.*— к. пришлифовать.

**ПРИШЛИФО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— шомартып җайлаштырылу.

**ПРИ'ШЛЫЙ** — читтән килгән, читтән килеп урнашкан.

**ПРИШПАНДО'РИВАТЬ** *несов.*— к. пришпандорить.

**ПРИШПАНДО'РИТЬ** *сов.*— 1. *сапож.* шпандырьлау, шпандырьлап кую, каеш белән беркетеп кую; 2. *перен. просторен.* сугу, сыдыру (мәсәлән, атка чыбыркы белән).

**ПРИШПИ'ЛИВАТЬ** *несов.*— к. пришпилить.

**ПРИШПИ'ЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— кадап куелу (шпилька белән).

**ПРИШПИ'ЛИТЬ** *сов.*— кадап кую (шпилька белән).

**ПРИШПО'РИВАТЬ** *несов.*— к. пришпорить.

**ПРИШПО'РИТЬ** *сов.*— 1. шпорлау, шпор белән чәнчеп алу; *пришпорить коня* — атны шпорлау; 2. *перен. разг.* ашыктыру.

**ПРИШТУКОВА'ТЬ** *сов. порт.*— җөе беленмәслек итеп ямау, җөе беленмәслек итеп ямап кую.

**ПРИШТУКО'ВЫВАТЬ** *несов.*— к. приштуковать.

**ПРИШТУКО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд. порт.*— җөе беленмәслек итеп ямалу.

**ПРИЩЁЛКИВАТЬ** *несов.* — шартлату; *прищёлкивать языком* — тел шартлату.

**ПРИЩЁЛКНУТЬ** *сов.* — 1. шартлату, шартлатып кую; *прищёлкнуть языком* — телне шартлату (шартлатып кую); 2. *разг. фам.* кыстыру; *прищёлкнуть палец крышкой сундука* — бармакны сандык капкачына кыстыру.

**ПРИЩЕМИ'ТЬ** *сов.*— кыстыру; кысу, кыстырып имгәтү.

**ПРИЩЕМЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. прищемить.

**ПРИЩЕМЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— кыстырылу; кыстырып имгәтелү.

**ПРИЩЕ'П** *м. с.-х.*— 1. *только ед.* (*действие*) к. прищепить; 2. прищеп (агачка чыбыкча ялгау өчен ярылган урын); 3. (*привитое дерево*) чыбыкча ялганган агач.

**ПРИЩЕПИ'ТЬ** *сов.*, **ПРИЩЕПЛЯ'ТЬ** *несов. с.-х.*— (агачка) ярып ялгау, агачка чыбыкча ялгау (прививка ясау).

**ПРИЩЕ'ПОК** *м.*— 1. *с.-х.* чыбыкча (җимеш агачына ялгауда кулланыла); 2. *спец.* (*зажим для белья*) кыстыргыч, кер эләктергеч.

**ПРИЩИ'ПКА** *ж. мн.* нет, *с.-х.*— прищипка, үсемлекләрнең очын өзү (нормаль үссен өчен үсемлекләрнең кайбер яшь үренте башларын тырнак белән өзеп алу).

**ПРИЩИ'ПЫВАТЬ** *несов. с.-х.*— прищипка ясау, үсемлекләрнең очын өзү.

**ПРИЩИ'ПЫВАТЬСЯ** *несов. страд. с.-х.*— прищипка ясалу.

**ПРИЩУ'РИВАТЬ** *несов.*— к. прищурить.

**ПРИЩУ'РИВАТЬСЯ** *несов.*— к. прищуриться.

**ПРИЩУ'РИТЬ, ПРИЩУ'РИТЬСЯ** *сов.*— күзне кысу, күзне кыса төшү.

**ПРИЩУ'ЧИВАТЬ** *несов. просторен. фам.*— к. прищучить.

**ПРИЩУ'ЧИТЬ** *сов. простореч. фам.*— каты шелтәләү; янау.

**ПРИЮ'Т** *м.*— **1.** *книж. (пристанище)* торыр урын, куыш, сыеныр урын; **2.** *дореворл. (для сирот)* приют, ятимнәр йорты.

**ПРИЮТИ'ТЬ** *сов.*— урнаштыру, сыеныр урын бирү, сыендыру.

**ПРИЮТИ'ТЬСЯ** *сов.*— **1.** урнашу, сыену, оялау; *ласточка приютилась под крышей* — карлыгач түбә кыегы астына оялаган; **2.** *перен.* урнашу; *рядом с фабрикой приютился маленький домик* — фабрика янына кечкенә генә бер өй урнашкан.

**ПРИЮ'ТСКИЙ** *дореворл.*— приют...-ы; *приютские дети* — приют балалары.

**ПРИЯ'ЗНЕННО** *нареч. книж. устар.*— дусларча.

**ПРИЯ'ЗНЕННЫЙ** *книж. устар.*— яхшы теләктәге, яхшы теләкле, дус..., якын күрүчән.

**ПРИЯ'ЗНЬ** *ж. мн.* нет, *книж. устар.*— дуслык, дусларча мөнәсәбәт, якын күрү.

**ПРИЯ'МОК** *м. спец.*— чокыр (өйнең подвал тәрәзәсе алдында яки ишеге төбендә казылган чокыр; забойда су җыелу өчен эшләнгән чокыр).

**ПРИЯ'ТЕЛЬ** *м.*, **ПРИЯ'ТЕЛЬНИЦА** *ж.*— **1.** дус, әшнә; **2.** *фам.* туган, туганкай; *а я, приятель, сед*—ә минем, туганкай, чәчләрем агарган.

**ПРИЯ'ТЕЛЬСКИЙ** — дуслык...-ы, дусларча..., әшнәлек...-ы, әшнәләрчә...; *приятельские отношения* — дусларча мөнәсәбәт, дуслык мөнәсәбәтләре, әшнәлек мөнәсәбәтләре.

**ПРИЯ'ТНОСТЬ** *ж.*— **1.** *только ед.* ягымлылык, күңеллелек; **2.** рәхәт, ямь; *приятности сельской жизни*— авыл тормышының яме, авыл тормышының рәхәте.

**ПРИЯ'ТНЫЙ** — **1.** күңелле; *приятные вести* — күңелле хәбәрләр; **2.** тәмле; *приятный запах* — тәмле ис; **3.** ягымлы, сөйкемле, күңелгә ятышлы; *приятное лицо* — ягымлы йөз (чырай); **4.** *безл. в знач. сказ.* күңелле, күңелгә ошый. ◇ **Приятная погода** — яхшы һава.

**ПРИЯ'ТЬ** *сов. книж. ритор. устар.*— к. принять 1, 2, 3.

**ПРО** *предлог с вин. п.*—**1.** *разг.* турында, хакында; *говорить про кого-н.*— берәр кеше турында сөйләү; **2.** *простореч.* өчен; *это не про нас* — бу безнең өчен түгел. ◇ **Про запас** — саклык өчен, саклыкка. **Читать про себя** — эчтән уку, тавышсыз уку.

**ПРОАНАЛИЗИ'РОВАТЬ** *сов. книж.*— анализ ясау, анализ ясап чыгу.

**ПРОА'ХАТЬ** *сов. простореч.*— **1.** (берникадәр вакытны) ахылдап үткәрү; ахылдап чыгу; *проахал целый час* — бер сәгать вакытны ахылдап үткәрде; *проахал всю ночь* — төн буе ахылдап чыкты; **2.** *перен. неодобр.* кулдан ычкындыру, югалту, (нәрсәдән булса да) язу.

**ПРО'БА** I к.— **1.** *только ед.* *(действие)* к. пробовать; **2.** проба (материалның анализга алынган өлеше).

**ПРО'БА** II *ж.*— проба (алтын-көмешнең сафлык дәрәҗәсе һәм аны белдерә торган клеймә); *золото 56 пробы* — 56 нчы пробалы алтын. ◇ **Низкой пробы** — **1.** *(о золоте, серебре)* түбән пробалы; **2.** *перен.* түбән сыйфатлы, начар сыйфатлы.

**ПРОБАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. разг.*— канәгатьләнү, чикләнү; *пришлось пробавляться на охоте сухарями* — ауда сохари белән канәгатьләнергә туры килде.

**ПРОБА'ЛТЫВАТЬ** I *несов. разг.*— к. проболтать I.

**ПРОБА'ЛТЫВАТЬ** II *несов. разг.*— к. проболтать II.

**ПРОБА'ЛТЫВАТЬСЯ** I *несов. разг.*— **1.** к. проболтаться I; **2.** *страд.* болгатылу, тугылану, болгатып җиткерелү, туглап җиткерелү.

**ПРОБА'ЛТЫВАТЬСЯ** II *несов. разг.*— к. проболтаться II.

**ПРОБАРАБА'НИТЬ** *сов.*— **1.** (берникадәр вакытны) барабан кагып үткәрү, барабан сугып үткәрү; **2.** *разг.* шакылдатып алу; дыңгырдатып алу; *пробарабанил вальс* — вальс дыңгырдатып алды.

**ПРОБАСИ'ТЬ** *сов. разг. шутл.*— калын тавыш белән әйтеп кую; калын тавыш белән җырлап алу.

**ПРОБЕ'Г** *м.*— **1.** *спорт.* чабыш, узыш; *лыжный пробег* — чаңгыда узыш; **2.** *спец.* юлда булу; *паровоз находился в пробеге двое суток* — паровоз юлда ике тәүлек булды; **3.** *спец.* узу юлы, узган юл, узган ара; *суточный пробег паровоза* — паровозның бер тәүлек эчендә узган юлы.

**ПРОБЕ'ГАТЬ** *сов.*— **1.** (берникадәр вакытны) йөгереп үткәрү; йөгерешеп (уйнап) үткәрү; *дети всё утро пробегали в саду* — балалар бөтен иртәне бакчада йөгерешеп (уйнап) үткәрделәр; **2.** *разг.* югалып тору; *собака пробегала два дня*—эт ике көн буена югалып торды; **3.** йөгереп йөреп...-сыз калу, (мәшәкатьләнеп) йөри-йөри...-сыз калу; *он обед пробегал* — ул йөри-йөри төшке ашсыз калды.

**ПРОБЕГА'ТЬ** *несов.*— к. пробежать.

**ПРОБЕ'ГАТЬСЯ** *сов. разг.*— бераз йөгереп йөреп кайту, бераз йөгереп алу.

**ПРОБЕЖА'ТЬ** *сов.*— **1.** йөгереп үтү, йөгереп үтеп китү; йөгереп узу, йөгереп узып китү; *пробежать по коридору* — коридор буйлап йөгереп үтеп китү; *пробежать километр* — бер километр араны йөгереп узу; **2.** үтү; *паровоз пробежал в час 60 км* — паровоз бер сәгать эчендә 60 *км* үтте. ◇ **Холод пробежал по спине** — аркама салкын йөгерде, тәнем чымырдап китте. **Шёпот пробежал по залу** — залда пышылдаган тавышлар ишетелеп китте. **Дождик пробежал** — яңгыр явып үтте. **Пробежать глазами** *перен.*— күз йөгертеп чыгу, күз йөртеп чыгу, тиз-тиз генә укып чыгу.

**ПРОБЕЖА'ТЬСЯ** *сов.*— бераз йөгереп алу, бераз йөгереп йөрү.

**ПРОБЕ'Л** *м.*— **1.** буш урын, ара (язылмый яки басылмый калган урын); *оставить пробелы* — буш урыннар калдыру (китапта яки язуда); **2.** *перен.* житешсезлек, кимче-

лек; *пробелы в знаниях* — белемдәге кимчелекләр.

**ПРОБЕ'ЛИВАТЬ** *несов.*—к. пробелить.

**ПРОБЕ'ЛИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. пробелиться; 2. *страд.* агартылу, агартып чыгылу, агартып җиткерелү.

**ПРОБЕЛИ'ТЬ** *сов.*— 1. агарту, агартып чыгу; агартып җиткерү; *надо хорошенько пробелить стены* — стеналарны яхшы гына агартып чыгарга кирәк; *надо хорошенько пробелить полотно* — киндерне яхшы гына агартырга кирәк; 2. (берникадәр вакыт) агарту, агартып (берникадәр вакытны) үткәрү; *весь день пробелила полотно* — бөтен көнемне киндер агартып үткәрдем, көн буе киндер агарттым.

**ПРОБЕЛИ'ТЬСЯ** *сов.*— ап-ак булу, ап-ак агару.

**ПРО'БЕЛЬ** *ж.*— аксыл төс, аксыл оттенок.

**ПРОБЕ'ЛЬНЫЙ** *спец.*— 1. агарту...-ы; *пробельная камера* — агарту камерасы; 2. *ж. в. знач. сущ.* агарту камерасы (яки бүлеге); 3. *тип.* (хәреф, сүз, юл арасында) буш урын калдыру өчен хезмәт итә торган; *пробельный материал* — буш урын калдыру өчен хезмәт итә торган материал.

**ПРОБЕ'ЛЬЩИК** *м. спец.*— пробельщик, агартучы (эшче).

**ПРОБИВА'ТЕЛЬ** *м. спец.*— тишкеч.

**ПРОБИВА'ТЬ** *несов.*— к. пробить 1,2,3.

**ПРОБИВА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. пробиться 1, 3, 4; 2. *страд.* тишелү, үтәли тишелү, тишеп чыгарылу.

**ПРОБИВНО'Й** *спец.*— бәреп тишү...-ы; үтәли тишеп чыгу...-ы; *пробивная сила снаряда* — снарядның үтәли тишеп чыгу көче.

**ПРОБИ'ВОЧНЫЙ** *спец.*— тишү...-ы; *пробивочный инструмент* — тишү инструменты.

**ПРОБИРА'ТЬ** *несов.*—к. пробрать.

**ПРОБИРА'ТЬСЯ** *несов.*— к. пробраться.

**ПРОБИ'РЕР** *м. спец.*— 1. к. пробирщик; 2. *устар.* пробалар палаткасы мөдире.

**ПРОБИ'РКА** *ж.*— пробирка (бер башы йомык пыяла көпшә).

**ПРОБИ'РНЫЙ** *спец.*— 1. проба билгеләү...-ы, пробалар салу...-ы, пробалар тикшерү...-ы; *пробирное дело* — пробалар тикшерү эше; 2. пробалар тикшерүче, пробалар салучы; *пробирный мастер* — пробалар тикшерүче мастер, пробалар салучы мастер.

**ПРОБИ'РОВАТЬ** *несов. спец.*— 1. металлның күләмен һәм сыйфатын билгеләү (рудаларда, эретмәләрдә); 2. проба салу (алтын-көмеш әйберләргә).

**ПРОБИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— 1. металлның күләме һәм сыйфаты билгеләнү; 2. проба салыну.

**ПРОБИ'РЩИК** *м. спец.*— пробирщик, пробалар тешерүче (салучы) мастер.

**ПРОБИ'ТЬ** *сов.*— 1. (сугып, бәреп) тишү, үтәли тишү, үтәли тишеп чыгару; үтәли тишеп чыгу; *пробить стену* — стенаны тишү (үтәли тишү); *пуля пробила дверь* — пуля ишекне үтәли тишеп чыккан; 2. *разг. спец.* (юл, сукмак) салу; *пробить тропинку в лесу* — урман аша сукмак салу; 3. *спец.* суслэү, мүкләү, мүкләп чыгу; *пробить избу* — өйне мүкләп чыгу; 4. сугу; *пробило два часа* — сәгать икене сукты. ◇ **Пробить себе дорогу** *перен.* — үзенә юл ачу (берәр эштә зур уңышларга ирешү). **Вчера целый день пробила масло** — кичә көн буе май язып үткәрдем.

**ПРОБИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. *(прорваться)* ерып чыгу, үтү, үтеп чыгу; 2. *перен. разг.* әвәрә булу, азаплану; *пробиться день над задачей*—көн буе мәсьәләне чишеп азапландым; 3. *разг.* (зур мохтаҗлыклар, авырлыклар белән) барып җиту, зур мохтаҗлыклар күреп яшәү; *пробились кое-как до апреля* (М. Горький)—зур мохтаҗлыклар белән апрельгә барып җиттек; 4. *разг.* шытып чыгу, күтәрелү, үсеп чыгу; *пробилась наружу маленькая травка* — вак үлән үсеп чыккан. ◇**Пробиться в люди** *перен. разг. фам.*— кеше булу, аякка басу.

**ПРО'БКА** *ж.*— 1. пробка (пробка агачының кайрысы); 2. бөке; *бутылка без пробки* — бөкесез шешә; 3. *перен. разг.* тыгынлык (бер җиргә җыелып нормаль хәрәкәткә комачаулык итә торган әйберләр, мәсәлән, тимер юлда вагоннар). ◇ **Глуп, как пробка** *разг. фам.*— шыр тиле.

**ПРО'БКОВЫЙ** — пробка..., пробкадан ясалган (эшләнгән); *пробковая подошва* — пробкадан эшләнгән олтан. ◇**Пробковый дуб** — бөке имәне.

**ПРОБЛЕ'МА** *ж. книж.*— проблема (хәл итүне таләп итә торган, хәл итәлергә тиеш булган теоретик яки практик мәсьәлә).

**ПРОБЛЕМА'ТИКА** *ж. мн.* нет, *книж.*— проблематика, проблемалар.

**ПРОБЛЕМАТИ'ЧЕСКИЙ** *книж.*—1. проблематик, чишелеп җитмәгән; *проблематический вопрос* — проблематик мәсьәлә; 2. шөбһәле, шикле, икеле; *проблематические обещания* — икеле вәгъдәләр; *проблематические надежды* — шөбһәле өметләр.

**ПРОБЛЕМАТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— проблематиклык, чишелеп җитмәү.

**ПРОБЛЕМАТИ'ЧНЫЙ** *книж.*— к. проблематический.

**ПРОБЛЕ'МНЫЙ** *книж.*— проблемалы, проблема куелган, (берәр) проблеманы күтәреп чыккан, (берәр) проблеманы эченә алган; *проблемная статья* — проблемалы мәкалә.

**ПРО'БЛЕСК** *м.*— 1. кинәт ялтырап китү; 2. *перен.* чаткы; *проблески надежды* — өмет чаткылары.

**ПРОБЛЁСКИВАТЬ** *несов.*— ялт-йолт итеп китү, ялтырап-ялтырап китү.

**ПРОБЛЕСНУ'ТЬ** *сов.*— ялтырап китү, ялт итеп китү.

**ПРОБЛЕ'ЯТЬ** *сов.*— 1. мәәлдәп кую, акырып кую; *над ухом проблеял ягнёнок* — колагым янында сарык бәтие мәәлдәп куйды; 2. (берникадәр вакыт) мәәлдәү, (берникадәр вакытны) мәәлдәп үткәрү, мәәлдәп чыгу; *ягнёнок проблеял всю ночь* — сарык бәтие төн буе мәәлдәп чыкты.

**ПРОБЛИСТА'ТЬ** *сов. разг.*— 1. ялтырап тору; 2. *(блеснуть)* ялтырап китү, ялт итеп китү.

**ПРОБЛУДИ'ТЬ** *сов. обл.*— к. проблуждать.

**ПРОБЛУЖДА'ТЬ** *сов.*— (берникадәр вакыт) адашып йөрү, (берникадәр вакытны) адашып йөреп үткәрү.

**ПРО'БНЫЙ** I — 1. сынау өчен алынган, сынау өчен хәзерләнгән; *пробная партия товаров* — сынау өчен алынган товарлар партиясе; 2. сынау максаты белән..., сынау өчен...; *пробный пуск машины* — машинаны сынау өчен (сынау максаты белән) эшләтеп карау. ◇ **Пробный камень, пробный шар** *перен.*— сынау максаты белән эшләнгән эш (кулланылган алым), сынау максатына хезмәт итә торган нәрсә.

**ПРО'БНЫЙ** II — пробалы, пробасы күрсәтелгән; *пробное золото* — пробалы алтын.

**ПРО'БОВАТЬ** *несов.*— 1. сынау, сынап карау, тикшереп карау, чамалап карау; *пробовать свои силы* — үзеннен көченне сынап карау; 2. татып карау, авыз итү; ашап карау; *пробовать вино* — винoны татып карау; 3. тырышу, тырышып карау; *пробовать узнать* — белергә тырышу.

**ПРО'БОВАТЬСЯ** *несов. страд.*— сыналу, сынап каралу.

**ПРОБОДА'ТЬ** I *сов.*— сөзеп тишү.

**ПРОБОДА'ТЬ** II *несов. книж.*— тишү, тишеп чыгу.

**ПРОБОДЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— 1. к. прободать II; 2. тишелү, тишелеп чыгу.

**ПРОБО'ИНА** *ж.*— тишек, үтәли тишелгән урын. ◇ **Получить пробоину** — тишелү, тишелеп чыгу.

**ПРОБО'Й** *м.*— 1. *спец. (для навешивания замка)* бик атламасы; 2. *обл.* к. пробоина; 3. *тех.* к. пробойник.

**ПРОБО'ЙКА** *ж. спец.*— 1. тишкеч; 2. бер тотам сүс (көймә, судно, өй стеналарын мүкләүгә китә торган).

**ПРОБО'ЙНИК** *м. тех.*— тишкеч.

**ПРОБОЛЕ'ТЬ** *сов.*— 1. авырып чыгу, (берникадәр вакыт) авыру, (берникадәр вакытны) авырып үткәрү; *он всю зиму проболел* — ул кыш буе авырып чыкты; 2. авырту; *раненая рука проболит недолго* — яраланган кул озак авыртмас (тиз төзәлер).

**ПРОБОЛТА'ТЬ** I *сов. разг.*— 1. *(взболтать до конца)* болгату, туглау, болгатып җиткерү, туглап җиткерү; 2. (берникадәр вакытны) болгатып үткәрү, туглап үткәрү, (берникадәр вакыт) болгату, туглау, болгатып тору, туглап тору.

**ПРОБОЛТА'ТЬ** II *сов. разг.*— 1. (берникадәр вакытны юк-бар нәрсәләр сөйләп) лыкылдап үткәрү, лыгырдап үткәрү, сафсата сатып үткәрү; *проболтал целый час* — бер сәгать вакытны лыгырдап үткәрде; 2. сөйләп ташлау, әйтеп салу, телдән ычкындыру; *проболтать тайну* — серне сөйләп ташлау.

**ПРОБОЛТА'ТЬСЯ** I *сов. разг.*— (берникадәр вакытны) эшсез йөреп үткәрү, ары сугылып, бире сугылып йөрү.

**ПРОБОЛТА'ТЬСЯ** II *сов. разг.*— сөйләп ташлау, әйтеп салу, телдән ычкындыру, күп сөйләнеп серне ачу.

**ПРОБО'Р** *м.*— чәч юлы.

**ПРОБОРА'НИВАТЬ** *несов.*— к. проборонить.

**ПРОБОРА'НИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— тырмалап чыгылу.

**ПРОБО'РКА** *ж. простореч.*— 1. *только ед. (действие)* к. пробрать 1, 2, 4; 2. каты шелтә.

**ПРОБОРМОТА'ТЬ** *сов.*— мыгырданып кую.

**ПРОБОРОЗДИ'ТЬ** *сов.*— 1. *(провести борозду)* буразна яру, буразна ярып үтү; 2. тирән эз калдыру, тирән эз калдырып үтү, ярып үтү; *пароход проборoздил реку* — пароход елгаңы ярып үтеп китте.

**ПРОБОРОНИ'ТЬ** *сов.*— 1. *(пройти бороной вспаханное)* тырмалап чыгу; 2. (берникадәр вакыт) тырмалау, тырмалап үткәрү; *весь день проборонил* — көн буе тырмаладым.

**ПРО'БОЧНИК** *м.*— 1. *разг.* бөке суыргыч, штопор; 2. *(мастер, делающий пробки)* бөкече, бөкеләр ясаучы мастер.

**ПРО'БОЧНИЦА** *ж.*— 1. *(коробка для пробок)* бөке тартмасы, бөкеләр куя торган тартма; 2. к. пробочник 2.

**ПРО'БОЧНЫЙ** — бөке...-ы, бөке ясый торган; *пробочный завод* — бөке заводы.

**ПРОБРА'СЫВАТЬ** *несов. разг.*— к. пробросить, пробросать 1, 2.

**ПРОБРА'СЫВАТЬСЯ** *несов. разг.*— 1. к. проброситься; 2. *страд.* ...аша ыргытылу.

**ПРОБРА'ТЬ** *сов.*— 1. *перен. разг. (выбранить)* шелтәләү, әрләү, тиргәү; 2. *с.-х. обл.* утау, утап чыгу; *пробрать коноплю* — киндерне утап чыгу; 3. *простореч. спец.* чәч юлын ачу, (чәчне) икегә аеру, (чәчне) икегә аерып тарау; *пробрать волосы* — чәчне икегә аерып тарау; 4. *порт.* бөреп тегү, бөрмәләп тегү. ◇ **Мороз пробрал меня до костей** *разг.*— суык җелегемә үтте. **Пробрала дрожь** *разг.*— дерелдәп (калтырап) киттем. **Нас ничем не проберёшь** *разг.*— безне һичнәрсә белән дә җиңә алмассын. **Пробрал страх** *разг.*— курку басты, куркуга төште.

**ПРОБРА'ТЬСЯ** *сов.*— 1. *(*авырлыклар белән, көч-хәл белән) үтү, ерып чыгу; *с трудом пробраться сквозь чащу леса* — көч-хәл белән куе урман аша үтү; 2. сиздермичә генә (әкрен генә) керү, үтеп керү, яшеренеп үтү, кача-поса үтү (керү), кача-поса үтеп китү (кереп китү); *пробраться в свою комнату* — сиздермичә генә үз бүлмәңә үтү (керү).

**ПРОБРЕ'ДИТЬ** *сов.*— (берникадәр вакытны) саташып үткәрү, саташып чыгу; *больной всю ночь пробредил* — авыру төн буе саташып чыкты.

**ПРОБРЕ'ЗЖИТЬ** *сов. безл. разг.:* **пробрезжило утро** — яктыра башлады, таң сызыла башлады, таң ата башлады.

**ПРОБРЕНЧА'ТЬ** *сов. разг.*— 1. дыңгырдатып (берникадәр вакытны) үткәрү, чиртеп утыру, дыңгырдатып утыру (музыка

коралында белер-белмәс уйнап вакыт үткәрү); *он пробренчал весь вечер на рояле* — ул бөтен кичен рояль дыңгырдатып үткәрде; ул кич буе рояль дыңгырдатып утырды; 2. дыңгырдатып алу; чиртеп алу; *пробренчать песенку на рояле* — рояльдә берәр көй дыңгырдатып алу; *пробренчать песенку на балалайке*—балалайкада берәр көй чиртеп алу; 3. шылтырап кую, чыңгылдап китү, чылт итеп китү; *пробренчал колокольчик* — кыңгырау шылтырап куйды.

**ПРОБРЕСТИ'** *сов. разг.*— 1. сөйрәлеп бару, ничек кирәк алай бару, көч-хәл белән бару, әкрен генә үтеп китү; *пробрёл с версту и устал* — ничек кирәк алай бер чакрым чамасы бардым да арыдым; 2. *устар. обл.* кичеп чыгу (сай урыннан су аркылы чыгу); *лошади пробрели через реку* — атлар елганы кичеп чыктылар.

**ПРОБРИВА'ТЬ** *несов.*— к. пробрить.

**ПРОБРИВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— кырып алыну.

**ПРОБРИ'ТЬ** *сов.*— 1. (юл ясап уртасыннан чәчне) кырып алу; 2. (берникадәр вакытны чәч яки сакал-мыек) кырып үткәрү.

**ПРОБРИ'ТЬСЯ** *сов.*— (берникадәр вакытны) кырынып үткәрү.

**ПРОБРОДИ'ТЬ** *сов.*— (берникадәр вакытны) йөреп үткәрү.

**ПРОБРОСА'ТЬ** *сов. разг.*— 1. бер-бер артлы ыргытып тидерә алмау (мәсәлән, гранаталарны); 2. таратып бетерү, өләшеп бетерү (мәсәлән, уен карталарын); 3. (берникадәр вакытны) ыргытып үткәрү.

**ПРОБРОСА'ТЬСЯ** *сов. простореч.*—(әрәм-шәрәм итеп) бернәрсәсез калу, (саксыз туздырып) ...-сыз калу; *не бросайся деньгами — пробросаешься!*— акчаңны юкка әрәм-шәрәм итмә, акчасыз калырсың.

**ПРОБРО'СИТЬ** *сов. разг.*— 1. ... (аша) ыргыту, ... (аркылы) ыргыту; *пробросить через забор* — койма аркылы ыргыту; 2. *(сосчитать на счётах)* санау, исәпләү, салу; 3. счёт салганда ялгышу, артык салып җибәрү, ялгыш артык салу, ялгыш артык исәпләү; *пробросить пять рублей* — счёт салганда биш сумга ялгышу; 4. *(промахнуться)* ыргытып тидерә алмау.

**ПРОБРО'СИТЬСЯ** *сов. разг.*— к. пробросить 3, 4.

**ПРОБРЮЗЖА'ТЬ** *сов. разг.*—1. *(проворчать про себя)* мыгырдану, мыгырданып әйтеп кую, мыгырданып кую; 2. (берникадәр вакытны) мыгырданып үткәрү, мыгырданып тору; *старик пробрюзжал весь вечер* — карт бөтен кичен мыгырданып үткәрде.

**ПРОБУБНИ'ТЬ** *сов. разг.*—1. мыгырданып кую; *пробубнить в ответ* — мыгырданып җавап бирү; 2. (берникадәр вакытны) мыгырданып үткәрү; *пробубнил весь вечер* — бөтен кичен мыгырданып үткәрде.

**ПРОБУДИ'ТЬ** *сов.*—1. *книж.* уяту (йокыдан); 2. *перен.* уяту, тудыру, дәртләндерү; *пробудить желание* — теләк тудыру; 3. *разг.* (берникадәр вакыт) уяту, уятып (берникадәр вакытны) үткәрү; *пробудил его целый час* — мин аны уятып бер сәгать вакытымны үткәрдем.

**ПРОБУДИ'ТЬСЯ** *сов. книж.*—1. уяну; *пробудиться ото сна* — йокыдан уяну; 2. *перен.* уяну, туу; *пробудился интерес к литературе* — әдәбиятка кызыксыну туды; 3. *перен. книж.* уяну, җанлану; *природа пробудилась* — табигать җанланды.

**ПРОБУ'ДНЫЙ** *разг. редко* — йокыдан уянганда була торган; *пробудный кашель* — йокыдан уянганда була торган йөткерү

**ПРОБУЖДА'ТЬ** *несов. книж.*— к. пробудить 1, 2.

**ПРОБУЖДА'ТЬСЯ** *несов. книж.*—1. к. пробудиться; 2. *страд.* уятылу, (дәрт, теләк) тудырылу.

**ПРОБУРА'ВИТЬ** *сов.*— бораулап тишү, борау белән үтәли тишү, үтәли тишеп чыгару.

**ПРОБУРА'ВЛИВАТЬ** *несов.*— к. пробуравить.

**ПРОБУРА'ВЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— бораулап тишелү, борау белән үтәли тишелү.

**ПРОБУРИ'ТЬ** *сов. спец.*— 1. бораулау, бораулап тишү (җирне, тау токымын); 2. (берникадәр вакытны җир, тау токымын) бораулау, бораулап үткәрү; *пробурили целый месяц* — бер ай вакытны бораулап үткәрделәр.

**ПРОБУРЧА'ТЬ** *сов. разг.*—1. мыгырдап кую; *пробурчал какие-то слова* — ниндидер сүзләр мыгырдап куйды; 2. (берникадәр вакыт) мыгырдану, (берникадәр вакытны) мыгырданып үткәрү; *пробурчал целый час* — бер сәгать вакытны мыгырданып үткәрде, бер сәгать буе мыгырданды.

**ПРОБЧА'ТКА** *ж. мн.* нет, *тех.*— пробчатка, бөке имәне кайрысы (бөке ясауга китә).

**ПРОБЫ'ТЬ** *сов.*— (берникадәр вакыт) булу, тору.

**ПРОВА'ЖИВАТЬ** *несов. разг.*— әкрен генә җитәкләп йөртү, әкрен генә арлыбирле йөртү.

**ПРОВА'Л** *м.*—1. *только ед. (действие)* к. провалиться 3; 2. *(провалившееся место)* упкын, җимерелеп төшкән урын, ишелеп төшкән урын; чокыр; 3. *перен.* уңышсызлыкка очрау, уңышсызлыкка дучар булу; *провал новой пьесы* — яңа пьесаның уңышсызлыкка очравы. ◇ **Провал памяти** *перен.*— онытып җибәрү, хәтер югалып тору.

**ПРОВАЛА'НДАТЬСЯ** *сов. простореч.*— вакытны әрәмгә үткәрү, вакытны бушка үткәрү, вакытны эшсез йөреп үткәрү, тик йөреп гомер үткәрү.

**ПРОВА'ЛИВАТЬ** *несов.*— к. провалить 1, 2, 3, 4. ◇ **Проваливай!** *простореч.*— укчәнне күтәр! юк бул! кит моннан!

**ПРОВА'ЛИВАТЬСЯ** *несов.*—1. к. провалиться; 2. *страд.* җимерелү, җимереп төшерелү.

**ПРОВАЛИ'ТЬ** *сов.*— 1. җимерү, җимереп төшерү, ишеп төшерү; *провалить пол* — идәнне җимерү; 2. *перен. разг.* бозу, харап итү, юкка чыгару, үти алмау, башкарып чыга алмау; *провалить дело* — эшне юкка чыгару, эшне бозу; 3. *перен. разг.* кире кагу, кабул итмәү; *провалить предложение* —

тәкъдимне кире кагу; 4. *разг. фам. (на экзамене)* начар белгесе кую; 5. *простореч.* әкрен генә үтеп китү; агылып узып китү; *толпа провалила мимо* — халык төркеме әкрен генә үтеп китте.

**ПРОВАЛИ'ТЬСЯ** *сов.*—1. егылып төшү; *провалиться в погреб* — кар базына егылып төшү; 2. ватылу, ишелү, җимерелү; *лёд провалился* — боз ватылган; 3. җимерелү, җимерелеп төшү; уелу, уелып төшү, ишелү, ишелеп төшү; *крыша дома провалилась* — өй түбәсе ишелеп төшкән; 4. *перен. разг. фам.* китеп югалу; *куда ты провалился?* — син кая китеп югалдың? 5. *перен.* уңышсызлыкка очрау, уңышсызлыкка дучар булу, җимерелү, барып чыкмау; *планы провалились* — планнары уңышсызлыкка очрады, планнары җимерелде, планнары барып чыкмады. ◇ **Провалиться на экзамене** *разг.* — экзамен бирә (тота) алмау, экзаменда начар билгесе алу. **Провались!** *простореч. фам.* — кит моннан, бәйләнмә! Чәнчелеп кит! **Как сквозь землю провалился** *разг.* — җиргә сеңгәндәй булды. **Готов был сквозь землю провалиться** — җир үтә китәрлек булдым, җир тишегенә керердәй булдым (оялудан).

**ПРОВАЛЯ'ТЬ** *сов.*—1. *спец.* (киез) басу; *провалять войлок* — киез басу; 2. *разг.* (берникадәр вакыт киез) басу; (берникадәр вакытны киез) басып үткәрү; *целый день провалял валенки* — бөтен көнен киез итек басып үткәрде, көн буе киез итек басты.

**ПРОВАЛЯ'ТЬСЯ** *сов.*—1. эшсез яту, тик яту; *он всё лето провалялся* — ул җәй буе тик ятты; 2. кирәксезгә аунап яту; *вещь долго провалялась, а теперь пригодилась* — әйбер бик озак вакыт кирәксезгә аунап ятты, хәзер эшкә ярады.

**ПРОВАНСА'ЛЬ** *м. мн.* нет, *кулин.*— провансаль (соусның бер төре).

**ПРОВА'НСКИЙ** : **прованское масло** — прованс мае, зәйтүн мае (ашауга китә).

**ПРОВА'Р** *м. мн.* нет, *тех.*—1. *(действие)* к. проварить 3; 2. провар (металлның эретеп ябыштырылган җөендә эрү һәм ябышу тирәнлеге).

**ПРОВА'РИВАТЬ** *несов.*—1. к. проварить; 2. *спец.* сумалалау, вәрләү, вәр сөртү.

**ПРОВА'РИВАТЬСЯ** *несов.*—1. к. провариться; 2. *страд.* пешерел җиткерелү.

**ПРОВАРИ'ТЬ** *сов.*—1. *(сварить до полной готовности)* пешереп җиткерү; 2. (берникадәр вакыт) пешерү, кайнату, пешереп (берникадәр вакытны) үткәрү, кайнатып (берникадәр вакытны) үткәрү; *всё утро проварила варенье* — бөтен иртәсен вареньe кайнатып үткәрде; 3. *тех.* эретеп ябыштыру, җөенә эрегән металл кою.

**ПРОВАРИ'ТЬСЯ** *сов.*—1. пешеп җитү; *рыба проварилась* — балык пешеп җиткән; 2. (берникадәр вакыт) пешү; *каша проварится больше часа* — ботка бер сәгатьтән артык пешәр, ботка пешерүгә бер сәгатьтән артык вакыт китә.

**ПРОВА'ЩИВАТЬ** *несов. спец.*— к. провощить.

**ПРОВА'ЩИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— балавызлану, балавыз сөртелү.

**ПРОВЕВА'ТЬ** *несов.*— к. провеивать.

**ПРОВЕВА'ТЬСЯ** *несов.*—1. к. провеяться; 2. *страд.* җилгәрелү, җилгәреп чыгылу, суырылу, суырып чыгылу (суырылган ашлык турында).

**ПРОВЕ'ДАТЬ** *сов. разг.*—1. *(навестить)* кереп хәл белү, хәл белешү, хәл белеп чыгу, күреп чыгу; 2. *(узнать, дознаться о чем-н.)* белү, белешү.

**ПРОВЕ'ДЫВАТЬ** *несов. разг.*— к. проведать.

**ПРОВЕЗТИ'** *сов.*— (утыртып, төяп) алып бару, илтү; *провезти лесом* — урман аша алып бару.

**ПРОВЕ'ИВАТЬ** *несов.*— к. провеять.

**ПРОВЕ'ИВАТЬСЯ** *несов.*— к. провеваться.

**ПРОВЕНТИЛИ'РОВАТЬ** *сов.*— җилләтеп алу, һава алмаштырып алу, вентиляция ясап алу.

**ПРОВЕ'РЕННЫЙ** — тикшерелгән, сыналган.

**ПРОВЕ'РИТЬ** *сов.*—1. тикшерү, тикшереп чыгу; *проверить работу* — эшне тикшерү; 2. сынау, сынап карау, тикшерү; *проверить сотрудников на работе* — сотрудникларны эштә сынау; *проверить работу механизма* — механизмның эшләвен сынап карау. ◇ **Проверить часы** — сәгатьне дөресләү.

**ПРОВЕ'РКА** *ж. мн.* нет — тикшерү, сынау.

**ПРОВЕРНУ'ТЬ** *сов.*—1. *(пробуравить)* үтәли бораулап тишү; 2. борып чыгару, борып үткәрү; *провернуть винт через доску* — винтны такта аша борып чыгару; 3. *простореч. фам.* тиз генә эшләп ташлау, тиз генә хәл итү; *провернуть дело* — эшне тиз генә эшләп ташлау; *провернуть вопрос* — мәсьәләне тиз генә хәл итү. ◇ **Провернуть мясо через мясорубку** — итне мясорубкадан (ит машинасыннан) чыгару, итне мясорубкадан үткәрү.

**ПРОВЕ'РОЧНЫЙ** — тикшерү...-ы, сынау...ы; *проверочная комиссия* — тикшерү комиссиясе.

**ПРОВЕРТЕ'ТЬ** *сов.*—1. к. провернуть 1; 2. (берникадәр вакыт) әйләндерү, әйләндереп (берникадәр вакытны) үткәрү.

**ПРОВЕРТЕ'ТЬСЯ** *сов.*— (берникадәр вакыт) әйләнү, әйләнеп тору; *колесо провертелось несколько минут* — көпчәк берничә минут әйләнде.

**ПРОВЁРТЫВАТЬ** *несов.*— к. провертеть 2, провернуть 1.

**ПРОВЁРТЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*—1. бораулап үтәли тишелү; 2. борып чыгарылу, борып үткәрелү.

**ПРОВЕ'РЩИК** *м.*, **ПРОВЕ'РЩИЦА** *ж.*— тикшерүче, тикшереп торучы.

**ПРОВЕРЯ'ТЬ** *несов.*— к. проверить.

**ПРОВЕРЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— тикшерелү, сыналу, сынап каралу.

**ПРОВЕ'С** I *м. только ед. торг.* : **в этом мешке муки три кило провеса** — бу капчыкта он өч килога ким чыкты.

**ПРОВЕ'С** II *м. спец.*—1. сыгылып төшү,

сыгылып чыгу, салынып төшү (мәсәлән, түшәм, стена, тимер чыбык һ. б. ш. турында); 2. сыгылып төшкән урын, сыгылып чыккан урын, салынып төшкән урын.

**ПРОВЕ'СИТЬ** I *сов.*—ким үлчәү.

**ПРОВЕ'СИТЬ** II *сов. спец.*— каклау, һавада киптерү (балык турында).

**ПРОВЕ'СИТЬ** III *сов. спец.*—тигезләү, тигезлеген (турылыгын) тикшерү; *провесить стену* — стенаның тигезлеген тикшерү.

**ПРОВЕ'СИТЬСЯ** *сов.*—1. *торг. (ошибиться при взвешивании)* ялгыш үлчәү, үлчәгәндә ялгышу; 2. *спец. (провялиться)* каклану, һавада кибү.

**ПРОВЕСНО'Й** *обл.*, **ПРОВЕ'СНЫЙ** *торг.*— какланган, һавада киптерелгән.

**ПРОВЕСТИ'** *сов.*—1. үткәрү, уздыру; *провести мимо дома* — өй яныннан уздыру; *провести отряд через болото* — отрядны сазлык аша үткәрү; *провести успешно посевную кампанию* — чәчү кампаниясен уңышлы үткәрү; *провести железную дорогу* — тимер юл үткәрү (тимер юл салу); 2. сызу; *провести линию* — сызык сызу; 3. сыпыру, сыпырып җибәрү; *провести рукой по лицу* — битне кул белән сыпыру; 4. *спорт. (пробежать первым)* беренче булып килү; 5. *перен. разг. (обмануть)* алдау; 6. теркәп кую, язып кую; *провести по кассовой книге* — касса кенәгәсенә язып кую. ◇ **Провести в жизнь** — тормышка ашыру, тормышка үткәрү. **Провести электричество** — электр кертү, электр үткәрү.

**ПРОВЕ'ТРИВАТЬ** *несов.*— к. проветрить.

**ПРОВЕ'ТРИВАТЬСЯ** *несов.*—1. *разг.* к. проветриться; 2. *страд.* җилләтелү, җилләтеп алыну.

**ПРОВЕ'ТРИТЬ** *сов.*—1. җилләтү, җилләтеп алу, һавасын алмаштыру; *проветрить комнату* — бүлмәне җилләтеп алу; 2. *перен.* к. проветриться 3.

**ПРОВЕ'ТРИТЬСЯ** *сов. разг.*—1. җилләнү, һавасы алмашыну; *комната проветрилась* — бүлмә җилләнгән; 2. саф һавада йөреп кайту, (йөреп) һава алмаштыру; *поди на улицу, проветрись* — бар, урамга чык, (йөреп) һава алмаштыр; 3. *перен.* дөнья күреп кайту.

**ПРОВЕ'ШИВАНИЕ** *ср. мн.* нет, *геодез.*— маяклар утыртып чыгу, маяклар куеп чыгу.

**ПРОВЕ'ШИВАТЬ** I *несов.*— к. провесить.

**ПРОВЕ'ШИВАТЬ** II *несов. геодез.*— к. провешить.

**ПРОВЕ'ШИВАТЬСЯ** I *несов.*—1. к. провеситься; 2. *страд.* каклану, һавада киптерелү.

**ПРОВЕ'ШИВАТЬСЯ** II *несов. страд. геодез.*— маяклар куеп чыгылу, маяклар утыртып чыгылу.

**ПРОВЕШИ'ТЬ** *сов. геодез.*— маяклар куеп чыгу, маяклар утыртып чыгу; *провешить дорогу* — юлга маяклар куеп чыгу.

**ПРОВЕ'ЯТЬ** *сов.*—җилгәрү, җилгәреп чыгу, суыру, суырып чыгу; җилпү.

**ПРОВЕ'ЯТЬСЯ** *сов.*—җилгәрелү, суырылу.

**ПРОВИА'НТ** *м. мн.* нет — азык, азык-төлек, провиант.

**ПРОВИА'НТСКИЙ** *воен.*— азык...-ы; азык-төлек...-ы; провиант...-ы; *провиантские запасы* — азык-төлек запаслары.

**ПРОВИ'ДЕНИЕ** *ср. мн.* нет — (булачак вакыйгаларны) алдан күрү; *дар провидения* — (булачак вакыйгаларны) алдан күрү сәләте.

**ПРОВИДЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *церк.*— 1. тәкъдир; язмыш, алла кодрәте; 2. *перен.* алла, хак тәгалә.

**ПРОВИДЕНЦИАЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.*—1. язмыш; 2. провиденциализм (идеалистик философиядә тарихи вакыйгаларны тәкъдирдән килә дип аңлата торган агым).

**ПРОВИДЕНЦИА'ЛЬНЫЙ** *книж.*— провиденциаль, тәкъдирдән булган, язмыштан булган, тәкъдирдә язган, алладан булган.

**ПРОВИ'ДЕТЬ** *несов. книж.*— алдан күрү, киләчәкне күрү (белү).

**ПРОВИ'ДЕЦ** *м.*, **ПРОВИ'ДИЦА** *ж. книж. ритор. устар.*— алдан күрүче, киләчәктәге булуын белүче.

**ПРОВИЗЖА'ТЬ** *сов.*— 1. *(издать визг)* чыелдап кую, чинап кую; 2. (берникадәр вакыт) чыелдап үткәрү, чинап үткәрү, чинап чыгу, чыелдап чыгу; *собака провизжала всю ночь* — эт төн буе чинап чыкты.

**ПРОВИЗИО'НКА** *ж. разг. устар.*— провизионка, түләүсез билет (тимер юл эшчеләре һәм аларның семья членнарына местный поездга утырып йөрү өчен бирелә торган түләүсез билет).

**ПРОВИЗИО'ННЫЙ** — азык...-ы, азык-төлек...-ы; *провизионные склады* — азык складлары.

**ПРОВИ'ЗИЯ** *ж. мн.* нет — азык, азык-төлек, провизия.

**ПРОВИ'ЗОР** *м.*— провизор (махсус фармацевтик белем алган кешегә бирелә торган исем, звание).

**ПРОВИЗО'РНЫЙ** *книж.*—1. чама белән...-ган; *провизорная оценка* — чама белән бирелгән бәя; 2. вакытлыча...-ган, вакытлы; *провизорные меры* — вакытлы чаралар.

**ПРОВИНИ'ТЬСЯ** *сов.*— гаепле булу, гаеп эш эшләү, ялгышлык эшләп ташлау, хаталык эшләү.

**ПРОВИ'ННОСТЬ** *ж. разг.*— гаеп.

**ПРОВИНТИ'ТЬ** *сов.*— борып үтәли чыгару.

**ПРОВИНТИ'ТЬСЯ** *сов.*— (борылып) үтәли чыгу; *длинный винт провинтился насквозь* — озын винт үтәли чыкты.

**ПРОВИНЦИА'Л** *м. устар.*— 1. *(житель, уроженец провинции)* провинциал, провинция кешесе, провинциядә яшәүче кеше; 2. *перен. разг. пренебр.* провинциал (үзәк шәһәр гадәтләре белән таныш булмаган кеше).

**ПРОВИНЦИАЛИ'ЗМ** *м.*— провинциализм (1. *только ед. пренебр. устар.* провинция кешесенә хас булган сыйфат, караш; 2. *лингв. лит.* җирле диалектка хас булган сүз яки әйләнмә).

**ПРОВИНЦИА'ЛКА** *ж.*— к. провинциал.

**ПРОВИНЦИА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— к. провинциализм 1.

**ПРОВИНЦИА'ЛЬНЫЙ** — 1. провинция... -ы; *провинциальный человек* — провинция кешесе; 2. *устар.* провинциягә хас булган, провинция кешесенә хас булган; *провинциальные манеры* — провинция кешесенә хас булган кыланышлар.

**ПРОВИ'НЦИЯ** *ж.*— провинция (1. *истор.* борынгы Римды—римлылар тарафыннан яулап алынган өлкә; 2. кайбер дәүләтләрдә — административ берәмлек; 3. *истор.* XVIII йөздә Россиядә административ берәмлек; 4. *устар.* илнең башкаласыннан һәм зур культура үзәкләреннән ерак булган өлкәләре).

**ПРОВИ'НЧИВАТЬ** *несов.*— к. провинтить.

**ПРОВИ'НЧИВАТЬСЯ** *несов.*—1. к. провинтиться; 2. *страд.* борып үтәли чыгарылу.

**ПРОВИНЯ'ТЬСЯ** *несов. редко* —к. провиниться.

**ПРОВИРА'ТЬСЯ** *несов. простореч. фам.*— к. проврасться.

**ПРОВИСА'ТЬ** *несов.*— салыну, салынып тору, сыгылу, сыгылып тору.

**ПРОВИСЕ'ТЬ** *сов.*— (берникадәр вакыт) эленеп тору, тагылып тору, асылынып тору.

**ПРОВИСЕ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— җитәрлек эленеп тору.

**ПРОВИ'СНУТЬ** *сов.*— салыну, салынып төшү, бөгелү, сыгылу, сыгылып төшү.

**ПРО'ВОД** *м. тех.*— тимер чыбык, чыбык; *телефонный провод* — телефон чыбыгы.

**ПРОВОДИ'МОСТЬ** *ж. физ.*— электр тогы үткәрү, электр үткәрүчелек.

**ПРОВОДИ'МЫЙ** — үткәрелә торган; *меры, проводимые нами* — безнең тарафтан үткәрелә торган чаралар.

**ПРОВОДИ'НЫ** *ед.* нет, *обл. устар.*— к. проводы.

**ПРОВОДИ'ТЬ** I *несов.*— к. провести.

**ПРОВОДИ'ТЬ** II *сов.*—1. озату, озата чыгу, озата бару; *проводить гостей до ворот* — кунакларны капкага кадәр озатып чыгу; *проводить сына в армию* — улны армиягә озату; 2. озатып (карап) калу, арттан карап калу; *проводить глазами пешеходов* — җәяүлеләрнең артыннан карап калу; 3. йөртү; *провожу вас по залам музея* — мин сезне музей залларында йөртермен.

**ПРОВОДИ'ТЬСЯ** *несов. страд.*—1. үткәрелү, уздырылу; озатылу; 2. сызылу.

**ПРОВО'ДКА** *ж. мн.* нет —1. (*действие*) к. провести 1, 2, 6; 2. *тех.* үткәрмә, (тимер) чыбыклар челтәре; *электрическая проводка* — электр үткәрмә; 3. *спец.* йөртеп суындыру (атларны).

**ПРОВОДНИ'К** I *м.*—1. (*провожатый*) озатучы; озата баручы, юл күрсәтүче; 2. (*ж.-д. служащий*) проводник; 3. *истор.* (*почтовый ямщик*) почта ямщигы.

**ПРОВОДНИ'К** II *м.*— 1. *физ.* үткәргеч; 2. *перен.* үткәрүче, таратучы; *проводники культуры* — культура таратучылар.

**ПРОВОДНИ'ЦА** *ж.*— к. проводник I в 1, 2 знач.

**ПРОВО'ДЧИК** *м. спец.*— үткәрүче; *проводчик судов* — суднолар үткәрүче.

**ПРО'ВОДЫ** *ед.* *нет — озату.

**ПРОВОЕВА'ТЬ** *сов.*—1. (берникадәр вакыт) сугышу, сугышып үткәрү; *много лет провоевал Пётр I со шведами* — Пётр I бик күп еллар буена шведлар белән сугышкан; 2. *разг.* сугышка тоту; *много миллиардов провоевали европейские государства* — Европа дәүләтләре бик күп миллиардларны сугышка тоттылар.

**ПРОВОЁВЫВАТЬ** *несов. разг.*— к. провоевать 2.

**ПРОВОЖА'ТЫЙ** *м.*— озатучы, озата баручы; юл күрсәтүче.

**ПРОВОЖА'ТЬ** I *несов.*— к. проводить I.

**ПРОВОЖА'ТЬ** II *несов.*— к. проводить II.

**ПРОВОЖДА'ТЬ** *несов. книж. ритор. устар.*— к. провожать I, II.

**ПРОВО'З** *м. мн.* нет — к. провозить.

**ПРОВОЗВЕСТИ'ТЬ** *сов. книж. ритор. устар.*—1. (*предсказать*) алдан әйтү, алдан әйтеп бирү, алдан хәбәр бирү; 2. (тантаналы рәвештә) игълан итү.

**ПРОВОЗВЕ'СТНИК** *м.*, **ПРОВОЗВЕ'СТНИЦА** *ж. книж. ритор устар.*— алдан хәбәр бирүче.

**ПРОВОЗВЕЩА'ТЬ** *несов. книж. ритор. устар.*— к. провозвестить.

**ПРОВОЗВЕЩА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. алдан әйтелү, алдан әйтеп бирелү; алдан хәбәр бирелү; 2. тантаналы рәвештә игълан ителү.

**ПРОВОЗГЛАСИ'ТЬ** *сов. книж.*—1. (тантаналы рәвештә) игълан итү; 2. *устар.* игълан итү; *Пётр I провозгласил себя императором России* — Пётр I үзен Россия императоры дип игълан иткән. ◇ **Провозгласить тост** — тост күтәрү. **Провозгласить ура** — ура кычкыру.

**ПРОВОЗГЛАША'ТЬ** *несов. книж.*— к. провозгласить.

**ПРОВОЗИ'ТЬ** I *несов.*— 1. (утыртып яки төяп) йөртү; 2. к. провезти.

**ПРОВОЗИ'ТЬ** II *сов.*— (берникадәр вакытны йөк) ташып үткәрү.

**ПРОВОЗИ'ТЬСЯ** I *несов. страд.*— (утыртып, төяп) йөртелү, ташылу (атта, машинада һ. б.).

**ПРОВОЗИ'ТЬСЯ** II *сов. разг.*—1. (берникадәр вакытны) мәшәкатьләнеп үткәрү; (берникадәр вакыт) мәш килү, мәшәкатьләнү, мәшәкатьләнеп чыгу; *всю ночь провозился с больным* — төн буе авыру белән мәшәкатьләндем; 2. (берникадәр вакытны) шаярып үткәрү, (берникадәр вакыт) шаяру, шаярып чыгу; *ребятишки весь день провозились на полу* — балалар бөтен көнне идәндә шаярып үткәрделәр.

**ПРОВОЗНО'Й** *обл.*, **ПРОВО'ЗНЫЙ** — йөк ташыган өчен алына (түләнә) торган; илткән өчен..., алып барган өчен...; *провоз-*

*ная плата* — йөк ташыган өчен түләнә торган акча.

**ПРОВОЗОСПОСО'БНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *ж.-д.* — поездлар үткәрү мөмкинлеге.

**ПРОВОКА'ТОР** *м.* — **1.** провокатор (провокация таратучы яшерен агент); **2.** *перен. разг.* котки салучы, котки башы, котыртучы.

**ПРОВОКА'ТОРСКИЙ** — провокатор...-ы; провокаторлар...-ы; котки салучы...-ы; котки салучылар...-ы; провокаторлык...-ы; *провокаторская деятельность* — провокаторлык эше.

**ПРОВОКА'ТОРША** *ж.* — к. провокатор.

**ПРОВОКАЦИО'ННЫЙ** — провокацион; провокация максаты белән...-ган; *провакационный план* — провокацион план; *провокационный вопрос* — провокация максаты белән бирелгән сорау.

**ПРОВОКА'ЦИЯ** *ж.* — **1.** провокация (а. полициянең революцион оешмага үтеп кергән яшерен агентларының шул оешманы тар-мар итүгә юнәлдерелгән хыянәтчел эшләре; б. берәр капиталистик ил тарафыннан икенче бер илгә шпионаж һәм корткычлык алып бару өчен җибәрелгән яшерен агентларның хыянәтчел эшләре); **2.** провокация, котырту, котки, котки салу (хыянәтчел рәвештә); **3.** *мед.* авыруны кузгату.

**ПРОВОКИ'РОВАТЬ** *несов. устар.* — к. провоцировать.

**ПРОВОЛА'КИВАТЬ** *несов.* — к. проволочить.

**ПРО'ВОЛОКА** *ж. мн.* нет — тимер чыбык.

**ПРОВОЛО'КА** *ж. обл.* — к. проволóчка.

**ПРО'ВОЛОЧИНА** *ж. разг.* — тимер чыбык кисәге.

**ПРОВОЛОЧИ'ТЬ** *сов. простореч.* — **1.** к. проволочь; **2.** (берникадәр вакытны) файдасызга үткәрү, эшсез үткәрү.

**ПРОВОЛОЧИ'ТЬСЯ** *сов.* — **1.** *разг. фам.* сөйрәлеп йөреп үткәрү; *всю свою молодость проволочился за женщинами* — бөтен яшьлеген хатын-кызлар артыннан сөйрәлеп йөреп үткәрде; **2.** *простореч.* к. проволочься.

**ПРОВОЛО'ЧКА** *ж. разг.* — (эштә) тоткарлык.

**ПРО'ВОЛОЧНЫЙ** — **1.** тимер чыбык...-ы; *проволочное производство* — тимер чыбык производствосы; **2.** тимер чыбык..., тимер чыбыктан ясалган; *проволочная изгородь* — тимер чыбыктан ясалган киртә.

**ПРОВОЛО'ЧЬ** *сов. разг.* — сөйрәп алып китү, сөйрәп узып китү, өстерәп алып китү.

**ПРОВОЛО'ЧЬСЯ** *сов. разг.* — сөйрәлеп узып китү, сөйрәлеп үтеп китү, көч-хәл белән үтеп китү.

**ПРОВОНЯ'ТЬ** *сов. простореч.* — **1.** сасып бетү; *ведро провоняло* — чиләк сасып беткән; **2.** исе сеңү, исе сеңеп бетү; *пальто провоняло нафталином* — пальтога нафталин исе сеңеп беткән; **3.** сасыту, сасытып бетерү, ... исе чыгару, ... исе тутыру; *всю комнату провонял дёгтем* — бөтен бүлмәне дегет исе белән сасытып бетергән.

**ПРОВОПИ'ТЬ** *сов. разг.* — **1.** *(испустить вопль)* акырып кую, кычкырып кую; **2.** *простореч.* (берникадәр вакытны) елап үткәрү, елап чыгу, кычкырып үткәрү, кычкырып чыгу; *всю ночь провопила от боли* — авыртудан төн буе елап чыкты.

**ПРОВОРА'ЧИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. проворотить.

**ПРОВОРА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд. простореч.* — буталу, болгатылу.

**ПРОВО'РИТЬ** *несов. простореч. шутл.* — бик тиз өлгерү, бик тиз булдыру (күпне); житез эшләү, тиз эшләп алу, тиз арада эшләп җиткерү.

**ПРОВОРКОВА'ТЬ** *сов.* — **1.** гөрләп кую; *голубь проворковал* — күгәрчен гөрләп куйды; **2.** гөрләп үткәрү, гөрләү; *в саду всё утро проворковала горлинка* — бакчада бөтен иртә буена урман күгәрчене гөрләде.

**ПРОВО'РНО** *нареч.* — тиз, бик тиз, тиз-тиз, җәһәт кенә, җитезлек белән.

**ПРОВО'РНЫЙ** — **1.** тиз, тиз-тиз; ашыгыч; *проворными шагами* — тиз-тиз адымнар белән; **2.** җитез, өлгер; *проворный парень* — җитез егет.

**ПРОВОРОВА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — урлап тотылу, урлый-урлый тотылу.

**ПРОВОРО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. проворроваться.

**ПРОВОРОЖИ'ТЬ** *сов. обл.* — (берникадәр вакытны) фал ачып үткәрү, (вакытны) күрәзәлек итеп үткәрү, багучылык итеп үткәрү.

**ПРОВОРО'НИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. проворонить.

**ПРОВОРО'НИТЬ** *сов. простореч.* — авыз ачып калу, коры калу, колак кагу.

**ПРОВОРОТИ'ТЬ** *сов. простореч.* — **1.** *(промешать)* болгату, бутау; **2.** *фам.* к. провернуть 3.

**ПРОВОРО'ЧАТЬСЯ** *сов. разг.* — як-якка әйләнеп (берникадәр вакытны) үткәрү, як-якка әйләнеп чыгу, әйләнә-тулгана чыгу; *всю ночь проворочался на постели* — төн буе як-якка әйләнеп чыктым.

**ПРОВО'РСТВО** *ср. мн.* нет — җитезлек, өлгерлек.

**ПРОВОРЧА'ТЬ** *сов.* — **1.** мыгырдап кую, мыгырдап әйтеп кую, мыгырданып кую; *он что-то проворчал* — ул нәрсәдер мыгырданып куйды; **2.** (берникадәр вакытны) мыгырданып үткәрү; *он проворчал весь вечер* — ул бөтен кичен мыгырданып үткәрде; **3.** ырылдап чыгу, (берникадәр вакыт) ырылдау; *собака проворчала всю ночь* — эт төн буе ырылдап чыкты.

**ПРОВО'РЬЕ** *ср. мн.* нет, *обл.* — к. проворство.

**ПРОВОЦИ'РОВАТЬ** *сов. и несов.* — **1.** котырту, провокация ясау; *провоцировать на выступление* — чыгыш ясарга котырту; **2.** ... чыгарырга маташу, провокация ясау; *фашисты провоцируют войну* — фашистлар сугыш чыгарырга маташалар; **3.** *мед.* авыруны кузгату.

**ПРОВОЩИ'ТЬ** *сов. спец.* — балавызлау, балавызлап чыгу, балавыз сөртү.

**ПРОВРА'ТЬ** *сов. разг. фам.*— (берникадәр вакытны) ялганлап үткәрү, (берникадәр вакыт) ялган сату.

**ПРОВРА'ТЬСЯ** *сов. простореч. фам.*— ялганы тотылу.

**ПРОВЫ'ТЬ** *сов.*— **1.** улап кую; *где-то далеко провыла собака* — кайдадыр еракта эт улап куйды; **2.** (берникадәр вакыт) улау, улап чыгу; *собака провыла до утра* — эт иртәнгә кадәр улап чыкты.

**ПРОВЯ'ЛИВАТЬ** *несов.*— к. вялить.

**ПРОВЯ'ЛИВАТЬСЯ** *несов.*— к. вялиться.

**ПРОВЯ'ЛИТЬ** *несов.*— к. вялить.

**ПРОВЯ'ЛИТЬСЯ** *несов.*— к. вялиться.

**ПРОГАДА'ТЬ** *сов.*— **1.** оттыру, аллану; *прогадал, не согласившись ехать*—китәргә ризалык бирмичә оттырдым; **2.** к. проворожить.

**ПРОГА'ДЫВАТЬ** *несов.*— к. прогадать.

**ПРОГА'ЛИНА** *ж. разг.*— **1.** ачыклык, аланлык, алан (урманда); *выйти на прогалину* — урман ачыклыгына чыгу; **2.** ачыклык, ачык урын; *светлая прогалина на свинцовом небе* — кургашсыман соры күк йөзендәге як-якты ачыклык; **3.** *обл.* ярык, тишек; *прогалина в стене* — стена ярыгы.

**ПРОГА'ЛОК** *м. обл.*— к. прогалина.

**ПРОГА'Р** *м.*, **ПРОГА'РИНА** *ж.*—**1.** *(в лесу)* янык; **2.** янып тишелгән урын, янган урын; *прогар в крыше* — өй түбәсенең янган урыны.

**ПРОГА'ЩИВАТЬ** *несов. разг. редко* — к. прогостить.

**ПРОГИ'Б** *м.*— **1.** *только ед.* к. прогнуться; **2.** *(место прогиба)* бөгелгән урын.

**ПРОГИБА'ТЬ** *несов.*— к. прогнуть.

**ПРОГИБА'ТЬСЯ** *несов.*— к. прогнуться.

**ПРОГИБИЦИОНИ'ЗМ** *м. экон.*— прогибиционизм (сәүдә эшендә тыю чаралары системасы).

**ПРОГИМНА'ЗИЯ** *ж. дореволю.*— прогимназия (4—6 класслы, тулы булмаган гимназия).

**ПРОГЛА'ДИТЬ** *сов.*— **1.** *(проутюжить)* үтүкләү, үтүкләп чыгу; **2.** (берникадәр вакыт) үтүкләү, үтүкләп үткәрү; *целый день сегодня прогладила* — бүген мин көн буе үтүкләдем, бүген мин көнемне үтүкләп үткәрдем.

**ПРОГЛА'ДИТЬСЯ** *сов.*— үтүкләнү.

**ПРОГЛА'ДЫВАТЬ** *несов.* — к. проглодать 1.

**ПРОГЛА'ДЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— кимереп тишелү.

**ПРОГЛА'ЖИВАТЬ** *несов.*—к. прогладить.

**ПРОГЛА'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— үтүкләнү, үтүкләп куелу.

**ПРОГЛА'ТЫВАТЬ** *несов.*— к. проглотить.

**ПРОГЛА'ТЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— йотылу, йотып җибәрелү.

**ПРОГЛОДА'ТЬ** *сов.*—**1.** кимереп тишү, кимереп тишеп чыгару; *крыса проглодала пол* — күсе идәнне кимереп тишеп чыгарган; **2.** (берникадәр вакыт) кимерү; *собака весь вечер проглодала кость* — эт кич буе сөяк кимерде.

**ПРОГЛОТИ'ТЬ** *сов.*— **1.** йоту, йотып җибәрү; *проглотить пищу* — азыкны йоту; **2.** *разг. фам.* йомып калдыру, төшереп калдыру, искә алмау; кагылып кына китү, искә алып кына китү; **3.** *разг. фам.* бик тиз укып чыгу; *проглотить книгу* — китапны бик тиз укып чыгу. ◇ **Проглотил язык** — телен йоткан, авызына су капкан, авызына төймә капкан (дәшми). **Язык проглотишь** — телеңне йотарсың (тәмле). **Как (или будто, словно) аршин проглотил** — к. аршин. **Проглотить оскорбление** *разг. фам.*— мәсхәрәгә түзеп калу.

**ПРОГЛЯДЕ'ТЬ** *сов.* — **1.** карап чыгу, караштыргалап чыгу, күздән үткәрү, күз йөгертеп чыгу; *проглядеть газеты* — газеталарны караштыргалап чыгу; **2.** күрми калдыру, игътибар бирми калдыру; *проглядеть ошибку* — хатаны күрми калдыру; **3.** (берникадәр вакытны) карап үткәрү, карап тору; *целый час мы проглядели на пожар* — без бер сәгать буе янгын карап тордык. ◇ **Проглядеть глаза** *разг.*— (күп эшләп) күзне бозу, күзләрне бозу. **Все глаза проглядела** *перен.*— көтә-көтә күзләрем талып бетте, көтә-көтә көтек булып беттем.

**ПРОГЛЯ'ДЫВАТЬ** *несов.*— **1.** күренү, күренеп-күренеп китү; *звезды проглядывают сквозь облака* — болытлар арасыннан йолдызлар күренеп-күренеп китә; **2.** к. проглядеть.

**ПРОГЛЯНУ'ТЬ** *сов.*— **1.** күренү, күренеп китү; *на небе проглянула луна* — күктә ай күренде; **2.** беленү, сизелү, сизелеп китү, чагылу, чагылып китү; *во взоре его проглянула злоба* — аның күз карашында ачу чагылып китте.

**ПРОГНАТИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *анат.*— прогнатизм (ияк сөягенең алга нык чыгып торуы).

**ПРОГНАТИ'ЧЕСКИЙ** *анат.*— прогнатик; *прогнатическое строение лица* — йөзнең прогнатик төзелешле булуы.

**ПРОГНА'ТЬ** *сов.*— **1.** куу, куып җибәрү, куып чыгару; *прогнать из комнаты* — бүлмәдән куып чыгару; **2.** *разг.* куып узу, куып алып китү; *только что прогнали стадо* — көтүне яна гына куып алып киттеләр; **3.** *обл.* куу, агызу; *прогнать плоты* — сал агызу; **4.** *простореч.* кагып үтәли чыгару; *прогнать гвоздь сквозь доску* — кадакны кагып такта үтәли чыгару; **5.** *простореч.* үтү, узу; *прогнал верхом 20 км* — атка атланып 20 *км* үткән. ◇ **Прогнать дурной запах** — начар исне бетерү. **Прогнать тяжёлые думы** — авыр уйларны тарату, кайгы-хәсрәтне тарату. **Прогнать дремоту**—йокыны качыру. **Прогнать скуку** — эч пошуны бетерү, күнелне ачу.

**ПРОГНА'ТЬСЯ** *сов. разг.*—(берникадәр вакыт) куып бару.

**ПРОГНЕ'ВАТЬ** *сов. устар.*— ачуландыру, ачуын кабарту, ачуын чыгару, ачуын китерү.

**ПРОГНЕ'ВАТЬСЯ** *сов. устар.*— ачулану, ачуы кабару, ачуы чыгу. ◇ **Не прогневайся или не прогневайтесь**—**1.** *устар.* гаеп итмә, гаеп итмәгез; хәтерен (хәтерегез) калмасын; **2.** *теперь ирон.* кешегә ачуланма, үзең гаепле, үзеңә үпкәлә.

**ПРОГНЕВИ'ТЬ** *сов. устар.*— к. прогневать.

**ПРОГНИВА'ТЬ** *несов.*— к. прогнить.

**ПРОГНИ'ТЬ** *сов.*—үтәдән-үтә черү, череп бетү.

**ПРОГНО'З** *м. книж.*— прогноз (авыру, һава торышы һәм башка күренешләр һәм вакыйгаларның билгеләренә карап, аларның үсеше яки булачак нәтиҗәсе турында әйтеп бирү).

**ПРОГНОИ'ТЬ** *сов.*— черетү, черетеп бетерү.

**ПРОГНО'СТИКА** *ж. мн.* нет, *книж.*— прогностика (прогноз кую алымнары).

**ПРОГНОСТИ'ЧЕСКИЙ** *книж.*— прогностик; *прогностический вывод* — прогностик нәтиҗә.

**ПРОГНУСА'ВИТЬ** *сов. разг.*— к. прогнусить.

**ПРОГНУСИ'ТЬ** *сов. разг.*— борын аша әйтеп кую, тыңкышланып әйтеп кую.

**ПРОГНУ'ТЬ** *сов.* — бөгү, сыгып төшерү; *книги прогнули полку* — китаплар киштәне сыгып төшергән.

**ПРОГНУ'ТЬСЯ** *сов.*— бөгелү, сыгылу, сыгылып төшү.

**ПРОГОВА'РИВАТЬ** *несов.*— к. проговорить.

**ПРОГОВА'РИВАТЬСЯ** *несов.*— к. проговориться.

**ПРОГОВОРИ'ТЬ** *сов.*— **1.** әйтү, әйтеп кую; *проговорить несколько слов* — берничә сүз әйтү (әйтеп кую); **2.** (берникадәр вакытны) сөйләшеп үткәрү, сөйләшеп чыгу; сөйләшеп тору; *приятели проговорили всю ночь* — дуслар төн буе сөйләшеп чыктылар.

**ПРОГОВОРИ'ТЬСЯ** *сов.* — ялгыш серне ачып салу, ялгыш әйтеп салу, ялгыш ычкындыру, ычкындырып ташлау.

**ПРОГОЛОДА'ТЬ** *сов.*— (берникадәр вакыт) ач тору.

**ПРОГОЛОДА'ТЬСЯ** *сов.*— ачыгу, карын ачу, ашыйсы килү.

**ПРОГОЛОСИ'ТЬ** *сов.*— **1.** *обл.* сузып кычкырып кую; **2.** (берникадәр вакытны) елап үткәрү, елап чыгу, (берникадәр вакыт) елау; *вдова проголосила весь день* — тол хатын бөтен көнен елап үткәрде, тол хатын көн буе елады.

**ПРОГОЛОСОВА'ТЬ** *сов.*— **1.** тавыш бирү; **2.** тавышка кую; *проголосовать резолюцию* — резолюцияне тавышка кую; **3.** *разг.* (берникадәр вакытны) тавыш биреп үткәрү, (берникадәр вакыт) тавыш бирү; тавыш биреп бетерү.

**ПРОГО'Н** *м.*— **1.** *только ед. (действие)* к прогнать 2; **2.** *обл.* көтү урамы, көтү тыкрыгы; **3.** *обл.* көтү юлы; **4.** *истор.* прогон, юл акчасы, юл хакы (почта атларына утырып барган өчен түләнә торган акча).

**ПРОГО'НКА** *ж.*— **1.** *только ед. (действие)* к. прогнать **2, 3, 4**; **2.** *тех.* прогонка (винтны сырлау инструменты).

**ПРОГО'ННЫЙ** — **1.** көтү куа торган; *прогонная дорога*—көтү куа торган юл; **2.** прогон...-ы; почта атларына утырып барган өчен түләнгән; *прогонные деньги* — прогон акчасы; **3.** сал белән китерелгән, агызып китерелгән; *прогонный лес* — сал белән китерелгән агачлар.

**ПРОГОНЯ'ТЬ** I *несов.*— к. прогнать.

**ПРОГОНЯ'ТЬ** II *сов. простореч.*—(берникадәр вакытны) йөреп үткәрү; *три дня прогонял взад и вперёд* — өч көн вакытны анда-монда йөреп үткәрдем.

**ПРОГОНЯ'ТЬСЯ** I *несов. страд.*— **1.** куылу, куып җибәрелү, куып чыгарылу; **2.** агызылу (сал турында).

**ПРОГОНЯ'ТЬСЯ** II *сов разг.*— куып йөреп (берникадәр вакытны) үткәрү.

**ПРОГОРА'ТЬ** *несов.*— к. прогореть.

**ПРОГОРЕ'ТЬ** *сов.*— **1.** *разг.* янып бетү; *дрова в печке прогорели* — мичтәге утын янып бетте; **2.** *разг.* янып бозылу, янып тишелү; *сковорода прогорела совсем*—таба янып тишелгән; **3.** (берникадәр вакыт) яну, янып тору; *лампа прогорела всю ночь* — лампа төн буе янып торган; **4.** *перен. разг.* бөлү, банкрот булу; *акционерная компания прогорела* — акционерлар компаниясе бөлгән; **5.** *перен. разг. фам. шутл.* уңмау, яну, пешмәү; *моё дело прогорело* — минем эшем уңмады.

**ПРОГО'РКЛОСТЬ** *ж. мн.* нет — әчү, әче тәм керү, бозылу.

**ПРОГО'РКЛЫЙ** — әчегән, әче тәм кергән, бозылган.

**ПРОГО'РКНУТЬ** *сов.*— әчү, бозылу, әче тәм керү.

**ПРОГОРЛА'НИТЬ** *сов. разг. неодобр.*— **1.** акырып кую, бакырып кую, кычкырып кую; **2.** (берникадәр вакытны) акырынып үткәрү, бакырынып үткәрү, кычкырынып үткәрү; (берникадәр вакыт) акырыну, бакырыну, кычкырыну; *прогорланил весь вечер* — бөтен кичен акырынып үткәрде, кич буе акырынды.

**ПРОГОСТИ'ТЬ** *сов. разг.*— (берникадәр вакыт) кунак булу, кунак булып тору, кунакта үткәрү.

**ПРОГРА'ММА** *ж.*— программа.

**ПРОГРА'ММНЫЙ** *книж.*— программа...-ы, программ..., программа характерында булган, программа характерындагы; *программный документ* — программ документ.

**ПРОГРАФИ'ТЬ** *сов.*—графалау, графалап чыгу.

**ПРОГРАФЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. прографить.

**ПРОГРАФЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— графалану, графалап чыгылу.

**ПРОГРЕБА'ТЬ** *несов.*— к. прогрести.

**ПРОГРЕБА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— көрәлү, көрәп ташлану, көрәп чистартылу.

**ПРОГРЕВА'ТЬ** *несов.*— к. прогреть.

**ПРОГРЕВА'ТЬСЯ** *несов.*—**1.** к. прогреться; **2.** *страд.* үтәдән-үтә җылытылу, бик нык җылытылу, кыздырылу, бик нык кыздырылу.

**ПРОГРЕМЕ'ТЬ** *сов.*— **1.** гөрселдәп кую, гөрелдәп кую; *прогремела пушка* — туп гөрселдәп куйды; **2.** таралу, яңгырау; *имя героя прогремело на весь мир* — геройның исеме бөтен дөньяга яңгырады. ◇ **Гром прогремел всю ночь — төн буе күк күкрәде.**

**ПРОГРЕ'СС** *м.*— **1.** *книж.* прогресс, алга бару; *прогресс техники* — техниканың алга

баруы; 2. *разг.* прогресс, унайлану, яхшыру; *в его здоровье замечается прогресс* — аның сәламәтлегенең яхшыруы сизелә.

**ПРОГРЕССИ'ВКА** *ж. мн.* нет, *разг.*— прогрессивка (эш башыннан башкарылган эш нормасын арттырып үтәгән өчен түләнә торган хезмәт хакы).

**ПРОГРЕССИ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— прогрессивлык.

**ПРОГРЕССИ'ВНЫЙ** *книж.*— 1. прогрессив, үсә бара торган; *прогрессивный налог*— прогрессив налог; 2. прогрессив, алдынгы; *все прогрессивное человечество борется за мир* — бөтен прогрессив кешелек дөньясы тынычлык өчен көрәшә.

**ПРОГРЕССИ'РОВАТЬ** *несов. книж.* — 1. алга бару, үсү; *человечество прогрессирует* — кешелек дөньясы алга бара; 2. көчәю, көчәя бару; *болезнь прогрессирует* — авыру көчәя бара.

**ПРОГРЕ'ССИЯ** *ж. мат.*— прогрессия; *арифметическая прогрессия* — арифметик прогрессия.

**ПРОГРЕСТИ'** *сов.*— 1. көрәү, көрәп ташлау; *прогрести снег на дорожке* — юлдагы карны көрәп ташлау; 2. (берникадәр вакытны) ишеп үткәрү, (берникадәр вакыт) ишү; *прогрёб час и устал* — бер сәгать иштем дә арыдым.

**ПРОГРЕ'ТЬ** *сов.*— үтәдән-үтә җылыту, бик нык җылыту, кыздыру, бик нык кыздыру.

**ПРОГРЕ'ТЬСЯ** *сов.*— җылыну.

**ПРОГРОМЫХА'ТЬ** *сов. разг.*— 1. шапылдатып (шак-шок атлап) узып китү, үтеп китү; *прогромыхать по полу сапогами* — идән буйлап итекләре белән шак-шок атлап узып китү; 2. дыңгырдап үтеп китү, дөбердәп үтеп китү; *по улице прогромыхала карета* — урам буйлап (урамнан) карета дыңгырдап үтеп китте.

**ПРОГРОХОТА'ТЬ** *сов.*— гөрселдәп (алу) кую, дөбердәп (алу) кую; күкрәп кую (күк күкрәү турында).

**ПРОГРОХОТИ'ТЬ** *сов. тех.*— эре иләктән үткәрү, көшел иләге аша үткәрү.

**ПРОГРУЗИ'ТЬ** *сов.*— (берникадәр вакыт) йөк төяү, (берникадәр вакытны) йөк төяп үткәрү.

**ПРОГРУЗИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— к. прогрузить.

**ПРОГРЫЗА'ТЬ** *несов.*— к. прогрызть.

**ПРОГРЫЗА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. *разг.* к. прогрызться; 2. *страд.* кимереп тишелү, кимереп тишеп чыгарылу.

**ПРОГРЫ'ЗТЬ** *сов.*— 1. кимереп тишү, кимереп тишеп чыгару; 2. (берникадәр вакыт) кимерү, кимереп чыгу.

**ПРОГРЫ'ЗТЬСЯ** *сов. разг.*— тишеп чыгу, кимереп тишеп чыгу.

**ПРОГУДЕ'ТЬ** *сов.*— 1. кычкыру, кычкырту; *гудок прогудел* — гудок кычкыртты; 2. *разг.* колак тондыру, колак тондырып бетерү; *ты мне все уши прогудел* — син минем колакларымны тондырып бетердең; 3. (калын тавыш белән) кычкырып әйтеп кую; *прогудел басом над самым ухом* — колак төбендә калын тавыш белән кычкырып әйтеп куйды; 4. (берникадәр вакыт) кычкырту; *гудок прогудел две минуты* — гудок ике минут кычкыртты.

**ПРОГУ'Л** *м.*—прогул, эшкә чыкмау, эштән калу.

**ПРОГУ'ЛИВАТЬ** I *несов.*—1. к. прогулять 1; 2. саф һавада йөртү; *мать прогуливает детей* — ана балаларын саф һавада йөртә; 3. (*о лошадях*) йөртеп суыту.

**ПРОГУ'ЛИВАТЬ** II *несов.*— к. прогулять II.

**ПРОГУ'ЛИВАТЬСЯ** *несов.*— к. прогуляться.

**ПРОГУ'ЛКА** *ж.*— прогулка (күңел ачып саф һавада йөреп кайту).

**ПРОГУ'ЛОЧНЫЙ** — прогулка...-ы; *прогулочные лодки*— прогулка көймәләре. ◇ **Прогулочный шаг** — салмак адым.

**ПРОГУ'ЛЬНЫЙ** *разг.*— прогул...-ы, эшкә чыкмаган; *прогульный день* — прогул көне.

**ПРОГУ'ЛЬЩИК** *м.*, **ПРОГУ'ЛЬЩИЦА** *ж.*— прогулчы.

**ПРОГУЛЯ'ТЬ** I *сов.*— 1. (берникадәр вакытны) йөреп үткәрү; тик йөреп уздыру; *прогулял два часа по саду* — ике сәгать вакытны бакчада йөреп үткәрде; 2. *простореч.* йөреп...-сыз калу; ...-мый калу; *прогулял обед* — йөреп төшке ашсыз калды, йөреп ашамый калды; 3. *разг.* йокламау; *ребёнок прогулял почти всю ночь* — бала төн буе диярлек йокламады; 4. *простореч.* туздыру, туздырып бетерү, типтереп бетерү, җилгә очыру; *прогулял все свои деньги* — барлык акчасын туздырып бетергән; 5. *простореч.* типтереп (берникадәр вакытны) үткәрү; *прогулял всю ночь* — бөтен төнен типтереп үткәргән.

**ПРОГУЛЯ'ТЬ** II *сов.*— прогул ясау, эшкә чыкмау; *прогулял два дня* — ике көн эшкә чыкмады.

**ПРОГУЛЯ'ТЬСЯ** *сов.*— йөреп кайту, йөреп килү, саф һавада йөреп кайту, әйләнеп кайту.

**ПРОДАВА'ТЬ** *несов.*—к. продать. ◇ **Продаю, за что купил** *разг.*— ишеткәнемне сөйлим (гайбәт һ. б. турында).

**ПРОДАВА'ТЬСЯ** *несов.*— к. продаться.

**ПРОДАВЕ'Ц** *м.*— сатучы.

**ПРОДАВИ'ТЬ** *сов.*— басып яньчү, басып вату, басып сындыру; *продавить стекло* — пыяланы басып вату; *продавить крышку чемодана* —басып чемодан капкачын яньчү.

**ПРОДА'ВЛИВАТЬ** *несов.*— к. продавить.

**ПРОДА'ВЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— басып яньчелү, басып ватылу, басып сындырылу.

**ПРОДАВЩИ'К** *м. устар.*— к. продавец.

**ПРОДАВЩИ'ЦА** *ж.*— к. продавец.

**ПРОДА'ЖА** *ж. мн.* нет —1. (*действие*) к. продать; 2. сату, сатылу; *имеется в продаже* — сатылуда бар.

**ПРОДА'ЖНОСТЬ** *ж. мн.* нет — сатлык булу, сатылучан булу.

**ПРОДА'ЖНЫЙ** — 1. сатыла торган, сатлык; *продажные товары* — сатыла торган товарлар; 2. *перен.* сатлык, сатылучан; *продажная душа* — сатлык җан.

**ПРОДА'ЛБЛИВАТЬ** *несов.*— к. продолбить.

**ПРОДА'ЛБЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— чокып тишелү.

**ПРОДА'ТЬ** *сов.*— сату, сатып җибәрү.

**ПРОДА'ТЬСЯ** *сов.*— сатылу.

**ПРОДВИ'ГАТЬ** *сов.*— бер урыннан икенче урынга күчереп (берникадәр вакытны) үткәрү; *весь вечер продвигал мебель*— бөтен кичне җиһазларны бер урыннан икенче урынга күчереп үткәрдем.

**ПРОДВИГА'ТЬ** *несов.*— к. продвинуть.

**ПРОДВИ'ГАТЬСЯ** *сов.*— (берникадәр вакыт) йөрү, хәрәкәттә булу.

**ПРОДВИГА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. продвинуться; 2. *страд.* ...-рак күчереп куелу, алгарак күчерелү.

**ПРОДВИЖЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. (*действие*) к. продвинуть, продвинуться; 2. алга китеш, үсеш.

**ПРОДВИ'НУТЬ** *сов.*— 1. ...-рак күчереп кую, алгарак күчерү; *продвинуть шкаф к окну* — шкафны тәрәзә янынарак күчереп кую; 2. алып чыгу, алып керү, үткәрү; *надо продвинуть стол через дверь* — өстәлне ишектән алып чыгарга кирәк; 3. *перен.* җиткерү, җибәрү; *надо продвинуть литературу в деревню* — әдәбиятны авылга җиткерергә кирәк; 4. *перен. разг.* алга җибәрү; *надо продвинуть дело* — эшне алга җибәрергә кирәк; 5. *перен. разг.* күтәрү; *продвинуть по службе*—хезмәт буенча күтәрү.

**ПРОДВИ'НУТЬСЯ** *сов.*— 1. алга күчү, алга китү; *полк продвинулся на десятки километров* — полк уннарча километрга алга китте; 2. чыгу, үтү; *стол легко продвинулся через дверь* — өстәл ишектән бик җиңел үтте; 3. *перен.* күтәрелү; *продвинуться по службе* — хезмәт буенча күтәрелү; 4. *перен. разг.* алга китү; *дело продвинулось* — эш алга китте.

**ПРОДЕБАТИ'РОВАТЬ** *сов. книж.*— бәхәс алып бару, бәхәсләшеп алу, фикер алышу.

**ПРОДЕВА'ТЬ** *несов.*— к. продеть.

**ПРОДЕВА'ТЬСЯ** *несов.*— к. продеться.

**ПРОДЕЖУ'РИВАТЬ** *несов. разг.*— к. продежурить.

**ПРОДЕЖУ'РИТЬ** *сов.*— (берникадәр вакытны) дежур торып үткәрү, дежур тору, кизү тору.

**ПРОДЕКЛАМИ'РОВАТЬ** *сов.* — (нәфис итеп) уку, сөйләү; *продекламировать стихотворение*— шигырь уку.

**ПРОДЕ'ЛАТЬ** I *сов.*— ясау, тишү, ую; *проделать дверь в стене* — стенада ишек тишү.

**ПРОДЕ'ЛАТЬ** II *сов. разг.*— 1. эшләү, башкару, башкарып чыгу, үтәү; *проделать огромную работу* — бик зур эш башкару; 2. ясап (берникадәр вакытны) үткәрү, эшләп үткәрү; *целый час проделал упражнения* — бер сәгать вакытны күнегүләр ясап үткәрдем. ◇ **Проделать фокус** — фокус күрсәтү.

**ПРОДЕ'ЛКА** *ж.*— эш, кыланыш, кылану (гадәттә гаеп итәрлек).

**ПРОДЕ'ЛЫВАТЬ** I *несов.*— к. проделать I.

**ПРОДЕ'ЛЫВАТЬ** II *несов.*— к. проделать II.

**ПРОДЕ'ЛЫВАТЬСЯ** I *несов. страд.*— ясалу, тишелү.

**ПРОДЕ'ЛЫВАТЬСЯ** II *несов. страд.*— башкарылу, башкарып чыгылу, эшләнү, үтәлү.

**ПРОДЕМОНСТРИ'РОВАТЬ** *сов.*— күрсәтү, күрсәтеп алу.

**ПРОДЁРГАТЬ** *сов.*— 1. *простореч.* саплау (җепне энәгә); 2. *с.-х. обл.* (*проредить*) сирәкләү, сирәкләп чыгу; 3. (берникадәр вакыт) йолку, йолкып (берникадәр вакытны) үткәрү; *целый день продёргала лён* — көне буе җитен йолкып үткәрдем; 4. тартышу; *весь день продёргал плечом* — көн буе кулбашы тартышты.

**ПРОДЁРГИВАТЬ** *несов.*— к. продёрнуть, продёргать.

**ПРОДЁРГИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. *разг.* к. продёрнуться; 2. *страд.* саплану; сирәкләнү, сирәкләп чыгылу.

**ПРОДЕРЖА'ТЬ** *сов.*— тоту, тотып тору; *больного продержали в больнице три месяца* — авыруны больницада өч ай тоттылар.

**ПРОДЕРЖА'ТЬСЯ** *сов.*— 1. тотынып тору; *несколько минут он продержался на одной руке* — берничә минут ул бер кулы белән тотынып торды; 2. түзү, чыдау, түзеп тору, чыдап тору.

**ПРОДЕ'РЗКИЙ** и **ПРОДЕ'РЗОСТНЫЙ** *книж. устар.*— бик әдәпсез, бик тупас, бик оятсыз.

**ПРОДЁРНУТЬ** *сов.*— 1. *разг.* к. продеть; 2. *перен. простореч. фам.* тешләү, эләктерү (мәсәлән, газетада тәнкыйтьләп чыгу); *его продёрнули в газете* — аны газетага эләктергәннәр.

**ПРОДЁРНУТЬСЯ** *сов. разг.*— к. продеться.

**ПРОДЕ'ТЬ** *сов.*— 1. саплау, күзләү; *продеть нитку в иголку* — энәгә җеп саплау; 2. тыгу, кертү; *продел голову в хомут* — башын камытка тыккан.

**ПРОДЕ'ТЬСЯ** *сов.*— саплану.

**ПРОДЕФИЛИ'РОВАТЬ** *сов. книж.*— тантаналы марш белән үтеп китү, бер-бер артлы тезелеп үтеп китү (мәсәлән, гаскәр яки демонстрациядә катнашучылар турында).

**ПРОДЕШЕВИ'ТЬ** *сов. разг.*— бик арзан хакка сатып җибәрү, бик арзан хакка сату, очсыз сату.

**ПРОДЕШЕВЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. продешевить.

**ПРОДИКТОВА'ТЬ** *сов.*— 1. әйтеп яздыру, әйтеп торып яздыру, диктовать итеп яздыру; *продиктовоть письмо* — хатны әйтеп яздыру; 2. *перен.* кабул итәргә мәҗбүр итү, көчләп тагу.

**ПРОДИРА'ТЬ** *несов. простореч.*— к. продрать.

**ПРОДИРА'ТЬСЯ** *несов. простореч.*— к. продраться.

**ПРОДЛИ'ТЬ** *сов. книж.*— озайту, дәвам иттерү; *продлить отпуск* — отпускны озайту.

**ПРОДЛИ'ТЬСЯ** *сов. книж.*— дәвам итү, сузылу, тартылу.

**ПРОДНАЛО'Г** *м. мн.* нет — продналог (1921 нче елны — нэп чорында продразвёрстка урынына кертелгән азыклата налог).

**ПРОДОВО'ЛЬСТВЕННИК** *м. спец.*— азык хәзерләүче, продовольственник (азык хәзерләү оешмасы эшчесе).

**ПРОДОВО'ЛЬСТВЕННЫЙ** — азык...-ы, азык-төлек...-ы; *продовольственный магазин* — азык магазины.

**ПРОДОВО'ЛЬСТВИЕ** *ср. мн.* нет — 1. азык, азык-төлек; *запасти продовольствия* — азык хәзерләп кую; 2. *книж.* к. продовольствовать.

**ПРОДОВО'ЛЬСТВОВАНИЕ** *ср. мн.* нет, *книж. устар.*— к. продовольствовать.

**ПРОДОВО'ЛЬСТВОВАТЬ** *несов. книж.*— азык белән тәэмин итү, азык-төлек белән тәэмин итү.

**ПРОДО'Л** *м. обл.*— үзән, елга үзәне.

**ПРОДОЛБИ'ТЬ** *сов.*— 1. чокып тишү, чокый-чокый тишү (тишеп чыгару); *дятел продолбил кору* — тукран агач кайрысын чокып тишкән; 2. (берникадәр вакыт) чоку, чокып тору; *целый день продолбил дятел дерево* — тукран көн буе агач чокыды.

**ПРОДОЛГОВА'ТОСТЬ** *ж. мн.* нет — озынчалык, озынча булу.

**ПРОДОЛГОВАТ'ЫЙ** — озынча.

**ПРОДОЛЖА'ТЕЛЬ** *м.*— дәвам иттерүче.

**ПРОДОЛЖА'ТЬ** *несов.*— дәвам иттерү; *продолжать работу* — эшне дәвам иттерү.

**ПРОДОЛЖА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. дәвам итү, сузылу; *разговор продолжался недолго* — сөйләшүләр озакка сузылмады; 2. *страд. разг.* дәвам иттерелү, озайтылу.

**ПРОДОЛЖЕ'НИЕ** *ср.*— 1. *(действие)* к. продолжить, продолжаться; 2. дәвам; *продолжение следует* — дәвамы бар. ◇ **В продолжение** — буена; *в продолжение часа* — бер сәгать буена.

**ПРОДОЛЖИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — озынлык; озаклык.

**ПРОДОЛЖИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. озын; *продолжительная зима* — озын кыш; 2. озак, озак вакыт...; *продолжительное отсутствие* — озак булмау; 3. озакка сузылган; *продолжительные овации* — озакка сузылган алкышлар.

**ПРОДО'ЛЖИТЬ** *сов.*— дәвам иттерү, озайту, сузу; *продолжить занятия до июля* — занятиеләрне июльгә кадәр дәвам иттерү; *продолжить отпуск* — отпускны озайту.

**ПРОДО'ЛЖИТЬСЯ** *сов.*— к. продолжаться I.

**ПРОДО'ЛЬНЫЙ** — 1. буйга...; буй...-ы; *продольная распилка* — пычкы белән буйга кисү; 2. буй...-ы; *продольная сторона здания* — бинаның буй ягы.

**ПРОДОРОЖИ'ТЬСЯ** *сов. разг. устар.*— артык бәя сорап сатып алучыларны куркыту (биздерү).

**ПРОДОТРЯ'Д** *м.*— продотряд (хәрби коммунизм чорында продразвёрстка буенча азык-төлек җыеп йөрүче эшче-крестьяннардан торган кораллы отряд).

**ПРОДОХНУ'ТЬ** *сов.*— тын алу, иркен сулыш алу. ◇ **Не продохнуть или не продохнёшь** — 1. тын алыр хәл юк (тынчу һава, начар ис); 2. *перен. ирон.* күплегеннән кая барырга белмәссен.

**ПРОДРАЗВЁРСТКА** *ж. мн.* нет — продразвёрстка (1918—21 нче елларда хәрби коммунизм чорында азык-төлек хәзерләү системасы).

**ПРОДРА'ТЬ** *сов. простореч.*— ерту, тишү. ◇ **Глаза продрать** *простореч. вульг.*— күзне йокыдан ачу; күз ерту.

**ПРОДРА'ТЬСЯ** *сов. простореч.*— 1. ертылу, тишелү, ертылып чыгу, тишелеп чыгу; *на локтях рубашка продралась* — күлмәкнең терсәкләре тишелгән; 2. *перен.* ерып чыгу; *продраться сквозь толпу* — халык төркемен ерып чыгу.

**ПРОДРЕБЕЗЖА'ТЬ** *сов.*— чылтырап китү, шылтырап китү. ◇ **Старые часы продребезжали пять часов** — иске сәгать бишне „шыгырдатты" (бишне сукты).

**ПРОДРЕМА'ТЬ** *сов.*— йоклар-йокламас үткәрү; *всю ночь продремал* — бөтен төнемне йоклар-йокламас үткәрдем.

**ПРОДРО'ГНУТЬ** *сов.*— туңып бетү, туңып калтырый башлау, өшеп бетү, күшегү.

**ПРОДРОЖА'ТЬ** *сов.*— (берникадәр вакыт) калтырап тору, дерелдәп тору.

**ПРОДУБИ'ТЬ** *сов. спец.*— (тирене) дуплау, кайры белән иләү.

**ПРОДУВА'ТЬ** *несов. разг.*— 1. к. продуть; 2. *разг.* үтәли өрдерү, үтәли исү, үтәли өрү; *ветерок продувает* — жил үтәли өрә.

**ПРОДУВА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. *простореч. фам.* к. продуться; 2. *страд.* өреп чистартылу, өрдереп чистартылу.

**ПРОДУВНО'Й** I *простореч.*— хәйләкәр, алдакчы.

**ПРОДУВНО'Й** II *тех.*— к. продувочный.

**ПРОДУ'ВОЧНЫЙ** *тех.*— өрдермәле, өрдерү...-ы; *продувочный клапан* — өрдерү клапаны.

**ПРОДУ'КТ** *м.*— 1. продукт; *продукты сельского хозяйства* — авыл хуҗалыгы продуктлары; 2. *только мн.* азык-төлек, азык, ашамлык әйберләре, продуктлар; 3. *книж.* нәтиҗә, продукт.

**ПРОДУКТИ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет — продуктивлык, нәтиҗәлелек, нәтиҗәле булу, файдалы булу.

**ПРОДУКТИ'ВНЫЙ** — 1. продуктив, нәтиҗәле, нәтиҗә бирүчән, файдалы; *продуктивный труд* — нәтиҗәле хезмәт; 2. *с.-х.* продукт бирә торган, продукт алу өчен үрчетелә торган (авыл хуҗалыгы продуктлары, мәсәлән, ит, май, сөт, йон һ. б. продуктларны бирә торган); *продуктивный скот* — продукт алу өчен үрчетелә торган терлек.

**ПРОДУКТО'ВЫЙ** — азык-төлек...-ы; *продуктовый магазин* — азык-төлек магазины (ашамлык әйберләре сата торган магазин).

**ПРОДУКТООБМЕ'Н** *м. мн.* нет, *экон.*—

продуктлар алмашу (продуктлар алмашу юлы белән тәэмин итү системасы).

**ПРОДУ'КЦИЯ** *ж. мн.* нет — 1. продукция; *колхозная продукция* — колхоз продукциясе; 2. *книж. устар.* житештерү, житештерү процессы; *старый способ продукции* — житештерү процессының иске ысулы.

**ПРОДУ'МАТЬ** *сов.* — 1. (берникадәр вакытны) уйлап үткәрү, уйланып чыгу; *всю ночь продумала* — төн буе уйланып чыктым; 2. төптән уйлау, яхшылап уйлау, ныклап уйлау, һәрьяклап уйлау; *продумать вопрос* — мәсьәләне төптән уйлау.

**ПРОДУ'МЫВАТЬ** *несов.* — к. продумать.

**ПРОДУ'МЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — төптән уйланылу, яхшылап уйланылу, ныклап уйланылу.

**ПРОДУ'ТЬ** *сов.* — 1. өреп чистарту, өрдереп чистарту; *продуть самовар* — самоварны өрдереп чистарту; 2. *безл.* салкын тию, суык тию, жил тию, жил бәрү; *не сиди у окна, тебя продует* — тәрәзә янында утырма, жил тияр үзеңә; 3. *простореч. фам.* оттырып бетерү; *продул все свои деньги* — барлык акчасын оттырып бетергән; 4. *разг.* (берникадәр вакытны) өреп үткәрү.

**ПРОДУ'ТЬСЯ** *сов. простореч. фам.* — 1. *(проиграться)* оттыру; 2. (берникадәр вакытны) үпкәләп үткәрү, үпкәләп тору.

**ПРОДУ'ШИНА** *ж.* — жиллек.

**ПРОДУШИ'ТЬ** *сов. разг.* — исен сеңдерү, исен сеңдереп калдыру, исе сеңеп бетү; *вся комната продушена духами* — бөтен бүлмәгә ислемай исе сеңгән.

**ПРОДУШИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — исе сеңү, исе сеңеп калу, исе сеңеп бетү; *весь продушился табаком* — үзенә тәмәке исе сеңеп беткән.

**ПРОДЫМИ'ТЬ** *сов.* — 1. төтен исе сеңдереп бетерү, тәмәке исе сеңдереп бетерү, төтен (тәмәке) исе сеңдерү; 2. *разг.* төтәтеп тору (берникадәр вакыт).

**ПРОДЫМИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. төтен исе сеңү, тәмәке исе сеңү, төтен (тәмәке) исе сеңеп бетү; *весь продымился* — үзенә төтен исе сеңеп беткән; 2. (берникадәр вакыт) төтәп тору.

**ПРОДЫРИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — к. продырявиться.

**ПРОДЫРЯ'ВИТЬ** *сов. разг.* — 1. үтәли тишү, тишеп чыгу; *снаряд продырявил броню* — снаряд броняны үтәли тишеп чыккан; 2. тишү, тишеп чыгару, туздырып бетерү; *продырявил на локтях свою куртку* — курткасының терсәкләрен тишеп чыгарган.

**ПРОДЫРЯ'ВИТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. *(получить пробоину)* үтәли тишелү, үтәли тишелеп чыгу; 2. *(износиться до дыр)* тишелү, тишкәләнеп бетү, тузып бетү.

**ПРОДЫРЯ'ВЛИВАТЬ** *несов. разг.* — к. продырявить.

**ПРОДЫРЯ'ВЛИВАТЬСЯ** *несов.* — к. продырявиться.

**ПРОДЫША'ТЬ** *сов. разг.* — (берникадәр вакыт) яшәү, тору.

**ПРОДЫША'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. *(отдышаться)* сулыш алу, ял итеп алу, (берничә тапкыр) иркен итеп сулау; 2. *(прогуляться на свежем воздухе)* саф һавада йөреп кайту.

**ПРОЕДА'ТЬ** *несов.* — к. проесть.

**ПРОЕДА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг. фам.* к. проесться; 2. эшсез ашап яту, әрәм тамак булып яту; 3. *страд.* ашауга тотылып бетү (акча турында).

**ПРОЕ'ЗД** *м.* — 1. *только ед. (действие)* к. проехать; 2. юл, үтә торган җир; *узкий проезд* — тар юл; 3. *(переулок)* тыкрык. ◇ **Деньги на проезд** — юллык акча.

**ПРОЕ'ЗДИТЬ** *сов.* — 1. йөртеп кайту; *проездить лошадь* — атны йөртеп кайту; 2. *разг.* юлга (акча) тоту, (акчаны) юлга тотып бетерү; *проездил сто рублей* — юлга йөз сум акча тоттым; 3. (берникадәр вакытны нәрсәгә дә булса утырып) йөреп үткәрү; *проездил на машине два часа* — ике сәгать вакытны машинага утырып йөреп үткәрдем.

**ПРОЕ'ЗДИТЬСЯ** *сов. разг.* — юлда йөреп акчаны тотып бетерү, акчаны юлга тотып бетерү.

**ПРОЕЗДНО'Й** — юл...-ы; *проездная плата* — юл хакы.

**ПРОЕ'ЗДОМ** *нареч. разг.* — барышлый, үтешли, узып барышлый.

**ПРОЕЗЖА'ТЬ** *несов.* — 1. к. проехать; 2. к. проездить 1, 2.

**ПРОЕЗЖА'ТЬСЯ** *несов.* — к. проехаться.

**ПРОЕЗЖА'ЮЩИЙ** *м., в знач. сущ.* — үтеп баручы, узып баручы, узгынчы, юлаучы.

**ПРОЕ'ЗЖИВАТЬ** *несов. спец.* — к. проездить 1.

**ПРОЕ'ЗЖИЙ** — 1. к. проезжающий; 2. (ат, машина белән) йөри торган, йөрерлек; *проезжая дорога* — йөри торган юл; 3. *в знач. сущ.* узгынчы, юлаучы, узып баручы.

**ПРОЕ'КТ** *м.* — проект (1. берәр төрле корылманың эшләнгән планы; *проект Волго-Донского канала* — Волга-Дон каналы проекты; 2. берәр төрле документның башлангыч тексты; *проект договора* — договор проекты; 3. *перен.* план, уй, ният; *в проекте была экскурсия в горы* — проектта тауларга экскурсия оештыру бар иде).

**ПРОЕКТА'НТ** *м.* — проектант, проект яклаучы.

**ПРОЕКТИ'ВНЫЙ** *мат.* — проектив; *проективная геометрия* — проектив геометрия.

**ПРОЕКТИ'РОВАТЬ** I *несов.* — 1. проект төзү, проектлаштыру; *проектировать дом* — йорт проекты төзү; 2. *перен. разг.* планлаштыру, уйлау; *проектировать поездку в мае* — китүне майга планлаштыру.

**ПРОЕКТИ'РОВАТЬ** II *несов. мат.* — проекцияләү, проекция төшерү, проекция сызу.

**ПРОЕКТИ'РОВАТЬСЯ** I *несов. страд.* — 1. проект төзелү; 2. планлаштырылу, уйлану.

**ПРОЕКТИ'РОВАТЬСЯ** II *несов. страд. мат.* — проекцияләнү, проекция төшерелү, проекция сызылу.

**ПРОЕКТИРО'ВЩИК** *м.* — проектчы, проект төзүче.

**ПРОЕ'КТНЫЙ** — 1. проектлар төзү...-ы; *проектное бюро* — проектлар төзү бюросы; 2. проектта күрсәтелгән, уйланылган; *проектная мощность* — проектта күрсәтелгән егәрлек.

**ПРОЕ'КТОР** *м. спец.*— проектор, проекцион аппарат.

**ПРОЕКЦИО'ННЫЙ** — проекцион; *проекционный фонарь* — проекцион фонарь.

**ПРОЕ'КЦИЯ** *ж.*— проекция (1. *мат.* берәр нәрсәнең яссылыкка төшерелгән геометрик сурәте; 2. *спец.* сурәтне, кинокадрларны экранда күрсәтү).

**ПРОЁМ** *м. тех.*— уелган урын, уем; *проём для двери* — ишек урыны, ишек өчен уелган урын.

**ПРОЕ'СТЬ** *сов.*— 1. кимереп тишү, кимереп тишеп чыгару; *мыши проели пол* — тычканнар идәнне кимереп тишеп чыгарганнар; 2. *разг.* ашау, үтәли тишү, үтәли тишеп чыгу; *ржавчина проела крышу* — тутык түбәне үтәли тишкән (ашаган); 3. *разг.* ашап бетерү, (ашауга) тотып бетерү; *проел все деньги* — бөтен акчаны (ашауга) тотып бетердем; 4. (берникадәр вакыт) ашау, ашап үткәрү; *проел целый час* — бер сәгать вакытны ашап үткәрде, бер сәгать буе ашады.

**ПРОЕ'СТЬСЯ** *сов. разг. фам.*— акчаны ашарга тотып бетерү, ашауга тотып бетерү.

**ПРОЕ'ХАТЬ** *сов.*— 1. үтү, узу; үтеп китү, узып китү; *проехать улицей* — урам буйлап үтеп китү; *проехать пять вёрст* — биш чакрым ара үтү; *проехать остановку* — остановканы үтеп китү; 2. юлда бару (килү), юлда булу, юлда үткәрү; *проехал пять дней* — биш көн юлда булдым.

**ПРОЕ'ХАТЬСЯ** *сов. разг.*—(утырып) йөреп кайту, барып кайту, күңел ачып йөреп кайту; *проехаться на пароходе* — пароходта йөреп кайту. ◇ **Проехаться на** *чей-нибудь* **счёт** (или по *чьему-нибудь* **адресу**) *фам.*— тәрттереп әйтү.

**ПРОЖА'РИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. прожариться; 2. *страд.* кыздырылу, куырылу.

**ПРОЖА'РИТЬ** *сов.*— 1. үтәлән-үтә кыздыру, яхшылап куыру; 2. *перен. разг. фам.* бик нык кыздыру, пешерү; *прожарило меня на пляже крымское солнце* — Кырым кояшы пляжда тәнемне пешергән.

**ПРОЖА'РИТЬСЯ** *сов.*— 1. кыздырылып (пешеп) житү, куырылып житү, куырылып пешү; *котлета прожарилась* — кәтлит кыздырылып житте; 2. *перен. разг. фам.* кызыну, бик нык кызыну; *прожариться на солнце* — кояшта бик нык кызыну.

**ПРОЖА'ТЬ** I *сов.*— 1. басып (кысып) яньчү; *прожать крышку в портсигаре* — портсигарның капкачын басып яньчү; 2. изеп үткәрү, изеп сыгу, сыгып чыгару; *прожать ягоды через решето* — җиләкне изеп иләк аша үткәрү.

**ПРОЖА'ТЬ** II *сов.*— 1. (берникадәр вакыт) уру, урып (берникадәр вакытны) үткәрү; *жница прожала весь день* — уракчы хатын бөтен көнен урып үткәрде, уракчы хатын көн буе урды; 2. уру, урып узу; *прожнёшь две полосы* — *тогда отдыхай* — ике кишәрлек ур да, шуннан соң ял ит.

**ПРОЖА'ТЬСЯ** *сов. простореч. фам.*— ерып чыгу, кысыла-кысыла үтү.

**ПРОЖДА'ТЬ** *сов.*— көтеп (берникадәр вакытны) үткәрү, көтеп тору.

**ПРОЖЕВА'ТЬ** *сов.* — яхшылап чәйнәү, чәйнәп җиткерү.

**ПРОЖЕВА'ТЬСЯ** *сов.*— чәйнәлү, яхшы чәйнәлү.

**ПРОЖЁВЫВАТЬ** *несов.*— к. прожевать.

**ПРОЖЁВЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. прожеваться.

**ПРОЖЕ'КТ** *м.*— 1. *устар.* к. проект; 2. *разг. ирон. неодобр.* прожект, тормышка ашмаслык план.

**ПРОЖЕКТЁР** *м. ирон. неодобр.*— прожектёр (тормышка ашмаслык планнар төзүче, тормышка ашмаслык планнар төзү белән мавыгучы).

**ПРОЖЕКТЁРСКИЙ** *ирон. неодобр.*— прожектёрлар...-ы, прожектёр...-ы, прожектёрлык...-ы; тормышка ашмаслык; *прожектёрский план* — тормышка ашмаслык план.

**ПРОЖЕКТЁРСТВО** *ср. мн.* нет, *ирон. неодобр.*— прожектёрлык (тормышка ашмаслык планнар белән мавыгу).

**ПРОЖЕКТЁРСТВОВАТЬ** *несов. ирон. неодобр.*— тормышка ашмаслык планнар төзү белән маташу (мавыгу), прожектёрлык итү.

**ПРОЖЕ'КТОР** *м.* — прожектор (көчле яктылык бирә торган прибор).

**ПРОЖЕКТОРИ'СТ** *м.* — прожекторчы, прожекторда эшләүче, прожекторда эшләүче белгеч.

**ПРОЖЕ'КТОРНЫЙ** — 1. прожектор...-ы; прожекторлар...-ы; *прожекторный свет* — прожектор яктысы; 2. прожектор(лар) белән...; *прожекторное освещение* — прожектор(лар) белән яктырту.

**ПРО'ЖЕЛТЬ** *ж.*— сары йөгергән (төс), саргылт оттеноклы (төс); *окраска синеватая с прожелтью* — сары йөгергән күгелҗем төс.

**ПРОЖЕ'ЧЬ** *сов.*— 1. яндырып тишү, көйдереп тишү; *прожгла платье утюгом* — күлмәген үтүк белән көйдереп тишкән; 2. *перен. разг.* бик нык кыздыру, яндыру; *южное солнце вас прожжёт* — сезне көньяк кояшы бик нык кыздырыр; көньяк кояшы тәнегезне пешерер; 3. *перен. разг.* бик нык тәэсир итү, көчле тәэсир калдыру; *его речь прожгла меня насквозь* — аның чыгышы мина бик нык тәэсир итте; 4. *разг.* (берникадәр вакыт) яндыру, яндырып чыгу; *всю ночь прожёг лампу* — төн буе лампа яндырып чыктым; 5. *разг.* (*о деньгах*) тарату, җилгә очыру, таратып бетерү, җилгә очырып бетерү. ◇ **Прожечь** или **прожигать жизнь** — типтереп яшәү, типтереп гомер итү.

**ПРОЖЕ'ЧЬСЯ** *сов. разг.*— үтәли янып чыгу, янып тишелү, көеп тишелү.

**ПРОЖЖЁНЫЙ** *разг. неодобр.*— үтә, үтә чыккан, явыз; *прожжёный плут* — үтә алдакчы.

**ПРОЖИВА'ТЬ** *несов.*— к. прожить.

**ПРОЖИВА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. *разг.* к. прожиться; 2. *страд.* тотылу, тотылып бетү (акча турында).

**ПРО'ЖИГА** *м.* и *ж. обл. бран.*— алдакчы, астыртын, хәйләкәр, эт кисшы.

**ПРОЖИГА'ТЕЛЬ** *м.*: **прожигатель жизни** *разг. неодобр.*— типтереп гомер итүче, типтереп яшәүче, гомерен бушка үткәрүче.

**ПРОЖИГА'ТЬ** *несов.*— к. прожечь.

**ПРОЖИГА'ТЬСЯ** *несов.*— к. прожечься.

**ПРОЖИДА'ТЬ** *несов. разг. редко* — к. прождать.

**ПРОЖИ'ЛИНА** *ж. обл.*— к. прожилка.

**ПРОЖИ'ЛКА** *ж.*— тамыр (1. ташта, агачта, металлда һ. б. була торган төсле юка буй катлам; 2. тәндә беленеп тора торган кан тамыры).

**ПРОЖИМА'ТЬ** *несов.*— к. прожать.

**ПРОЖИМА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. *простореч. фам.* к. прожаться; 2. *страд.* басып (кысып) яньчелү.

**ПРОЖИНА'ТЬ** *несов.*— к. прожать II.

**ПРОЖИНА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— урылу.

**ПРОЖИРА'ТЬ** *несов. простореч. вульг.*— к. прожрать.

**ПРОЖИРА'ТЬСЯ** *несов. простореч. вульг.*— к. прожраться.

**ПРОЖИ'РИВАТЬ** *несов. спец.*— к. прожирить.

**ПРОЖИ'РИВАТЬСЯ** *несов. спец.*— 1. к. прожириться; 2. *страд.* май сеңдерелү, майландырылу.

**ПРОЖИ'РИТЬ** *сов. спец.*— май сеңдерү, майлау.

**ПРОЖИ'РИТЬСЯ** *сов. спец.*— майлану, майланып бетү.

**ПРОЖИ'ТОЧНЫЙ** — яшәү өчен кирәкле, яшәү өчен кирәк булган.

**ПРОЖИ'ТЬ** *сов.*— 1. яшәү, тору; *прожить сто лет* — йөз ел яшәү; *прожили месяц в доме отдыха* — ял йортында бер ай тордык; 2. *разг.* тоту, тотып бетерү; *прожить все деньги* — барлык акчаны тотып бетерү.

**ПРОЖИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— акчаны тотып бетерү, акчаны туздырып бетерү, акча туздыру.

**ПРОЖО'РА** *м.* и *ж. обл.*— бирән, туймас тамак, ач күз, күп ашаучы, бирән корсак.

**ПРОЖО'РЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — бирәнлек, туймас тамаклык, туймас тамак булу, ач күзлелек, күп ашаучан булу.

**ПРОЖО'РЛИВЫЙ** — туймас тамак, ач күз, күп ашаучан, бирән.

**ПРОЖО'РСТВО** *ср. мн.* нет, *разг.*— к. прожорливость.

**ПРОЖРА'ТЬ** *сов. простореч. вульг.*— к. проесть 3, 4.

**ПРОЖРА'ТЬСЯ** *сов. простореч. вульг.*— к. проесться.

**ПРОЖУЖЖА'ТЬ** *сов.*— 1. безелдәп (бызылдап) очып узып китү, очып китү; *над головой прожужжала муха* — баш өстеннән чебен безелдәп очып узып китте; 2. безелдәп (бызылдап) чыгу, (берникадәр вакыт) безелдәү (бызылдау, бызлау); *жук весь вечер прожужжал* — коңгыз кич буе безелдәде. ◇ **Прожужжать уши** *разг.*— колакны тондыру, колак итеп ашау.

**ПРО'ЗА** *ж. мн.* нет — 1. *лит.* проза, чәчмә (шигырь белән язылмаган әсәр, чәчмә әсәр); 2. *перен.* проза (тормышның көндәлек ягы).

**ПРОЗАИ'ЗМ** *м. лит.*— прозаизм (шигырьләрдә прозага хас булган әйләнмәләр куллану).

**ПРОЗА'ИК** *м.*— 1. прозаик, проза белән язучы; 2. *перен. неодобр. устар.* вакчыл кеше; *неисправимый прозаик* — һич төзәлмәс вакчыл кеше.

**ПРОЗАИ'ЧЕСКИЙ** *книж.*— 1. *лит.* прозаик, проза белән язылган; *прозаические произведения* — прозаик әсәрләр; 2. *лит.* прозага хас булган; *прозаическое выражение* — прозага хас булган әйләнмә; 3. *(лишённый увлекательности, будничный)* прозаик, кызыксыз, эч пошыргыч, күңелсез; 4. *ирон.* (*корыстный*) комсыз, ач күзле, акчага хирыс, нәфесле.

**ПРОЗАИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— 1. прозага хас булганлык; 2. кызыксызлык, күңелсезлек; 3. *ирон.* комсызлык, ач күзлелек, акчага хирыслык, нәфеслелек.

**ПРОЗАИ'ЧНЫЙ** *книж.*— к. прозаический 2, 3, 4.

**ПРОЗАКЛА'ДЫВАТЬ** *сов.* и *несов. разг. устар.*— бәхәсләшеп оттырып бетерү, бәхәсләшә-бәхәсләшә оттырып бетерү. ◇ Голову свою прозакладываю — башымны кисәргә бирәм, башымны кисмәгә бирәм.

**ПРОЗВА'НИЕ** *ср.*— 1. *(прозвище)* кушамат; 2. *устар. обл.* фамилия, исем.

**ПРОЗВА'ТЬ** *сов.*— 1. (*дать прозвище*) кушамат бирү, ... дип атау; 2. *простореч.* чакырып (берникадәр вакытны) үткәрү, (берникадәр вакыт) чакыру; *целых полчаса прозвал я его в кино* — мин аны кинога чакырып ярты сәгать вакытымны үткәрдем.

**ПРОЗВА'ТЬСЯ** *сов. простореч.*— кушамат бирелү; ... дип аталу.

**ПРОЗВЕНЕ'ТЬ** *сов.*— 1. чыңлап китү, шылтырап китү, чыңлаган тавыш ишетелеп китү, шылтыраган тавыш ишетелеп китү; яңгырап китү, яңгырау; 2. ишетелеп китү; *прозвенели детские голоса* — балалар тавышы ишетелеп китте.

**ПРО'ЗВИЩЕ** *ср.*— кушамат.

**ПРОЗВОНИ'ТЬ** *сов.*— 1. шалтырау; *прозвонил телефон* — телефон шалтырады; 2. чыңлау, (чаң) кагу, тавыш ишетелү; *прозвонил колокол* — чаң какты; 3. *разг.* чаң кагып хәбәр итү, чаң кагып чакыру, шалтыратып чакыру; *уже прозвонили обедать* — чаң кагып төшке ашка чакырдылар; 4. чаң кагып тору, (берникадәр вакытны) чаң кагып үткәрү; *прозвонил целых полчаса* — ярты сәгать вакытны чаң кагып үткәрде, ярты сәгать чаң кагып торды; 5. (берникадәр вакыт) шалтырату, шалтыратып тору; *прозвонил по телефону целых полчаса* — ярты сәгать (буена) телефоннан шалтыратып тордым.

**ПРОЗВУЧА'ТЬ** *сов.*— 1. ишетелеп китү;

*где-то вдали прозвучали голоса* — кайдадыр еракта тавышлар ишетелеп китте; 2. шалтырау, шалтырап китү; шалтыраган тавыш ишетелеп китү; *прозвучал звонок* — звонок шалтырап китте; 3. яңгырау, сизелеп китү; *в его словах прозвучало неудовольствие* — аның сүзләрендә канәгатьсезлек яңгырады.

**ПРОЗЕВА'ТЬ** *сов.* — 1. авыз ачып калу, колак кагу, өлгермәү, өлгерми калу; *прозевать поезд* — поездга өлгермәү; 2. (берникадәр вакыт) иснәү, иснәп тору, (берникадәр вакытны) иснәп үткәрү; *прозевал весь вечер* — кич буе иснәде.

**ПРОЗЁВЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. прозевать 2.

**ПРОЗЕ'КТОР** *м. мед.* — прозектор (мәетләр яру белгече).

**ПРОЗЕ'КТОРСТВО** *ср. мн.* нет, **ПРОЗЕКТУ'РА** *ж. мн.* нет, *мед.* — прозекторлык, прозектор вазифасы.

**ПРОЗЕЛИ'Т** *м. книж.* — прозелит (1. *устар.* икенче дингә күчкән кеше, динен алыштырган кеше; 2. берәр нәрсәнең яңа тарафдары).

**ПРОЗЕЛИТИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.* — прозелитизм (1. *устар.* нинди дә булса бер тәгълимат тарафдарларын мөмкин кадәр күбрәк арттырырга тырышу; 2. нинди дә булса яңа тәгълиматка чын күңелдән бирелгәнлек).

**ПРОЗЕЛИ'ТКА** *ж. книж.* — к. прозелит.

**ПРОЗИМОВА'ТЬ** *сов.* — кышлау, кыш чыгу, кышны үткәрү.

**ПРОЗНАВА'ТЬ** *несов. простореч.* — к. прознать.

**ПРОЗНА'ТЬ** *сов. простореч.* — белү, белеп алу.

**ПРОЗОДЕ'ЖДА** *ж. мн.* нет — эш киеме (производствода бирелә торган кием).

**ПРОЗОРЛИ'ВЕЦ** *м.*, **ПРОЗОРЛИ'ВИЦА** *ж. книж. устар. ритор.* — үткен акыллы, зирәк кеше, алдан күрүчән, алдан күрә белүчән кеше.

**ПРОЗОРЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — үткен акыллылык, зирәклек, алдан күрә белүчәнлек.

**ПРОЗОРЛИ'ВЫЙ** — үткен акыллы, зирәк, алдан күрә белүчән. ◇ **Прозорливый ум** — үткен акыл.

**ПРОЗРА'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. үтә күренмәлелек, үтә күренмәле булу; 2. *перен.* сафлык, ачыклык, аңлаешлылык.

**ПРОЗРА'ЧНЫЙ** — 1. үтә күренмәле; *прозрачное стекло* — үтә күренмәле пыяла; 2. *перен.* саф, ачык, аңлаешлы; *прозрачный стиль пушкинской прозы* — Пушкин прозасының ачык стиле; 3. *перен.* ачык, аерымачык, ачыктан-ачык күренеп тора торган; *прозрачная цель* — ачык максат.

**ПРОЗРЕВА'ТЬ** *несов.* — к. прозреть.

**ПРОЗРЕ'ТЬ** *сов. книж.* — 1. *(стать зрячим)* күрә башлау, күзе ачылу; 2. *перен.* аңлый башлау, төшенә башлау, күз ачылу; *тут-то я и прозрел, когда узнал все подробности о нём* — аның турында бөтен нәрсәне җентекләп белгәч, минем күзем ачылды (аңлый башладым); 3. *перен. устар.* аңлап алу, тотып алу; *прозреть чью-либо мысль* — кемнең дә булса фикерен тотып алу.

**ПРОЗУ'БРИВАТЬ** I *несов. спец.* — к. прозубрить I.

**ПРОЗУ'БРИВАТЬ** II *несов. школьн. арго.* — прозубрить II.

**ПРОЗУБРИ'ТЬ** I *сов. спец.* — тешәү (уракны); (пычкының) тешләрен аеру.

**ПРОЗУБРИ'ТЬ** II *сов. школьн. арго* — 1. (мәгънәсен аңламыйча) ятлау, өйрәнү, ятлап чыгу; *прозубрить учебник насквозь* — дәреслекне (мәгънәсен аңламыйча) баштанаяк ятлап чыгу; 2. (берникадәр вакыт мәгънәсен аңламыйча) ятлау, өйрәнү; *прозубрить всю ночь* — төн буе ятлау.

**ПРОЗЫВА'ТЬ** *несов.* — к. прозвать 1.

**ПРОЗЫВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. прозваться; 2. *страд. простореч.* кушамат бирелү, ... дип аталу. ◇ **Ты как прозываешься?** — синең исемең ничек? Ни исемле син? Ни атлы син?

**ПРОЗЯБА'ТЬ** *несов.* — 1. *книж. устар. (расти, прорастать)* шыту, үсү, шытып чыгу, үсеп чыгу; 2. *перен. разг. пренебр. (вести бесцельную жизнь)* мәгънәсезгә яшәү, өметсез яшәү, тутыгып яшәү; 3. *простореч.* к. прозябнуть 1.

**ПРОЗЯ'БНУТЬ** *сов.* — 1. *разг. (сильно озябнуть)* туңып бетү, өшеп бетү, катып бетү, күшегү; 2. *устар. (произрасти)* үсү, үсеп чыгу, шыту, шытып чыгу.

**ПРОИГРА'ТЬ** *сов.* — 1. оттыру, отылу; *проиграть шахматную партию* — бер партия шахмат уенын оттыру; 2. оттыру, югалту; *проиграть время* — вакытны югалту; 3. *разг.* уйнап алу, уйнап күрсәтү; *проиграть мазурку на рояле* — рояльдә мазурка уйнап алу; 4. (берникадәр вакытны) уйнап үткәрү; *дети весь день проиграли на дворе* — балалар бөтен көннәрен ишек алдында уйнап үткәрделәр; 5. уйнап...-сыз калу, уйнап...-мый калу; *дети проиграли обед* — балалар уйнап ашамый калдылар.

**ПРОИГРА'ТЬСЯ** *сов.* — оттырып бетерү.

**ПРОИ'ГРЫВАТЬ** *несов.* — к. проиграть.

**ПРОИ'ГРЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. проиграться; 2. *страд.* оттырылу.

**ПРО'ИГРЫШ** *м.* — 1. оттыру, оттырыш; 2. *перен.* югалту, әрәм итү; *проигрыш времени* — вакыт югалту.

**ПРО'ИГРЫШНЫЙ** — оттырышлы.

**ПРОИЗВЕДЕ'НИЕ** *ср.* — 1. әсәр; *произведения Льва Толстого* — Лев Толстой әсәрләре; 2. *мат. (результат умножения)* тапкырчыгыш.

**ПРОИЗВЕСТИ'** *сов.* — 1. ясау, үткәрү; *произвести ремонт* — ремонт ясау; 2. тудыру; чыгару; *произвести шум* — тавыш чыгару; 3. (ясап) эшләп чыгару, житештерү; *произвести тысячу тонн пшеницы* — мең тонна бодай җитештерү; 4. *книж. (родить)* тудыру; 5. *дорев. офиц. (повысить в чине)* күтәрү. ◇ **Произвести хорошее впечатление** — яхшы тәэсир калдыру.

**ПРОИЗВОДИ'ТЕЛЬ** *м.* — 1. эшләп чыга-

ручы, житештерүче; 2. *биол.* үрчеткеч (нәселле ата терлек). ◇ **Производитель работ** *спец.* — прораб (төзү эшләрендә турыдан-туры житәкчелек итүче техник, инженер).

**ПРОИЗВОДИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет— 1. *книж.* файдалылык, нәтижәлелек, файдалы булу, нәтижәле булу; 2. житештерүчәнлек; *производительность труда* — хезмәт житештерүчәнлеге.

**ПРОИЗВОДИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.*— 1. файдалы, нәтижәле; *производительные расходы* — нәтижәле чыгымнар; 2. житештерүче, житештерү...-ы; *производительные силы* — житештерүче көчләр.

**ПРОИЗВОДИ'ТЬ** *несов.*—1. к. произвести; 2. китереп чыгару; *это слово производят от русского корня* — бу сүзне рус сүзе тамырыннан китереп чыгаралар. ◇ **Каких свет не производил** *разг.*— дөньяда булмаган, гомердә булмаган.

**ПРОИЗВОДИ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. ясалу; 2. (ясап) эшләп чыгарылу, житештерелү; 3. күтәрелү.

**ПРОИЗВО'ДНЫЙ** *книж.* — 1. ясалма, ясалган; *производное слово* — ясалма сүз; *слово „паровой" — производное от „пар"* — „паровой" сүзе „пар" сүзеннән ясалган; 2. *мат.* чыгарылма.

**ПРОНЗИ'ТЬ** *сов. книж.*— чәнчү, чәнчеп үтәли тишү, кадау; *пронзить штыком* — штык белән чәнчү. ◇ **Пронзить болью сердце** — йөрәкне әрнетү. **Пронзить взглядом** — тәэсирле итеп карау.

**ПРОНЗИ'ТЬСЯ** *сов. книж. редко* — үтү, үтәли үтү, ерып үтү.

**ПРОНИЗА'ТЬ** *сов.*— 1. (арасына) тезү; *пронизать промежутки жемчугом* — араларына энҗе тезү; 2. (берникадәр вакыт) җепкә тезү, җепкә тезеп (берникадәр вакытны) үткәрү; *пронизала бусы целый вечер* — бөтен кичен җепкә мәрҗән тезеп үткәрде. ◇ **Холод пронизал всё тело** — салкын үзәгемә үтте.

**ПРОНИ'ЗЫВАТЬ** *несов.*— к. пронизать.

**ПРОНИ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— (арасына) тезелү.

**ПРОНИ'ЗЫВАЮЩИЙ** *книж.*— 1. *(о холоде, ветре)* каты, ачы, үзәккә үтә торган; 2. *(о взгляде)* үткен.

**ПРО'НИЗЬ** *ж.*— 1. *устар.* сәйлән; 2. *только ед. собир. разг.* сәйлән тезмәсе, бер җеп сәйлән.

**ПРОНИКА'ТЬ** *несов. книж.*— к. проникнуть.

**ПРОНИКА'ТЬСЯ** *несов. книж.*— к. проникнуться.

**ПРОНИКНОВЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— 1. *(действие)* к. проникать; 2, к. проникновенность.

**ПРОНИКНОВЕ'ННО** *нареч.*— чын күңелдән, чын йөрәктән, тәэсирле итеп; *проникновенно говорить* — чын күңелдән сөйләү.

**ПРОНИКНОВЕ'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— чын күңелдән булу; тәэсирле булу; *говорить с большой проникновенностью* — чын күңелдән сөйләү, тәэсирле итеп сөйләү.

**ПРОНИКНОВЕ'ННЫЙ** *книж.*—1. *устар.* к. проникнутый 2; 2. чын күңелдән (сөйләнгән) әйтелгән; *проникновенные речи* — чын күңелдән сөйләнгән речьләр; 3. тәэсирле, тәэсир итәрлек; *проникновенный голос* — тәэсирле тавыш.

**ПРОНИ'КНУТЫЙ** — 1. *(напряжённо переживающий что-н.)* әсәрләнгән; 2. сугарылган; *проникнутый идеей долга перед социалистической Родиной* — социалистик Ватанга хезмәт итү идеясе белән сугарылган.

**ПРОНИ'КНУТЬ** *сов. книж.*—1. керү, үтеп керү; *проникнуть в комнату* — бүлмәгә керү; 2. барып җитү; *советские люди проникли к Северному полюсу* — совет кешеләре Төньяк котыпка барып җиттеләр; 3. *перен.* таралу, җәелү; *слух об этом проник повсюду* — бу турыдагы хәбәр бөтен җиргә таралды; 4. аңлау, төшенү; *проникнуть в чью-нибудь мысль* — кемнең дә булса фикерен аңлау.

**ПРОНИ'КНУТЬСЯ** *сов. книж:* **проникнуться сознанием долга** — үз бурычыңны тирәнтен аңлау; **проникнуться убеждением** — бик нык ышану, катгый карарга килү; **проникнуться любовью к родине** — ватанга мәхәббәт белән сугарылу.

**ПРОНИМА'ТЬ** *несов. разг.*— к. пронять.

**ПРОНИЦА'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— үткәрүчәнлек, үткәрү сәләте.

**ПРОНИЦА'ЕМЫЙ** — үткәрә торган, үткәрүчән.

**ПРОНИЦА'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет,

*книж.*— үткенлек, зирәклек, үтә күрүчәнлек.

**ПРОНИЦА'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.*—1. үткен; *проницательные глаза* — үткен күзләр; 2. үткен, зирәк, сизгер; *проницательный ум* — үткен акыл.

**ПРОНИЦА'ТЬ** *несов. книж. устар.*— к. проникать.

**ПРОНОСИ'ТЬ** I *несов.*— к. пронести.

**ПРОНОСИ'ТЬ** II *сов.*—1. (берникадәр вакыт) кию, киеп йөрү; *проносил шубу три года* — тунны өч ел кидем; 2. тишелгәнче кию; *проносить подмётки ботинок* — ботинкаларның олтаннары тишелгәнче кию; 3. (берникадәр вакыт) күтәреп йөрү, күтәреп йөртү; *больного ребёнка проносил всю ночь на руках* — авыру баланы төн буе кулыма күтәреп йөрттем.

**ПРОНОСИ'ТЬСЯ** I *несов.*— к. пронестись.

**ПРОНОСИ'ТЬСЯ** II *сов. разг.*— киелү, тузу, чыдау; *пальто проносилось три года* — пальто өч елга чыдады, пальто өч ел киелде.

**ПРОНО'СНЫЙ** *разг. устар.*— эч йомшарта торган, эч җибәрә торган.

**ПРОНУМЕРОВА'ТЬ** *сов.*— номерлап чыгу, номерлар сугып чыгу, сан сугу, сан сугып чыгу.

**ПРОНУМЕРО'ВЫВАТЬ** *несов.*— к. пронумеровать.

**ПРОНУМЕРО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— номерлап чыгылу, номерлар сугып чыгылу, сан сугылу, сан сугып чыгылу.

**ПРОНУНСИАМЕ'НТО, ПРОНУНЦИАМЕ'НТО** *нескл. ср. полит.*— пронунсиаменто (хәрби переворот).

**ПРОНЫ'РА** *м.* и *ж. разг. фам. пренебр.*— к. пройдоха.

**ПРОНЫ'РИВАТЬ** *несов.*— к. пронырнуть.

**ПРОНЫ'РЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *пренебр.*— әрсезлек, тыкшынучанлык.

**ПРОНЫ'РЛИВЫЙ** *разг. пренебр.*— к. пройдошный.

**ПРОНЫРНУ'ТЬ** *сов.*—1. чумып йөзеп чыгу; *пронырнуть от одного берега до другого* — чумып бер ярдан икенче ярга хәтле йөзеп чыгу; 2. *разг.* тиз генә кереп китү, үтеп китү; *пронырнуть в двери* — ишектән тиз генә кереп китү.

**ПРОНЫ'РСТВО** *ср. разг. неодобр.*— 1. *только ед.* к. пронырливость; 2. алдашу, алдау-йолдау.

**ПРОНЮ'ХАТЬ** *сов. разг.*—1. *фам. (разузнать)* астыртын сорашып белү, астыртын тикшереп белү, иснәнеп белү; 2. иснәп (берникадәр вакытны) үткәрү, (берникадәр вакыт) иснәп тору.

**ПРОНЮ'ХИВАТЬ** *несов. разг.*— к. пронюхать.

**ПРОНЮ'ХИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг. фам.*— астыртын сорашу нәтиҗәсендә беленү, астыртын тикшерү нәтиҗәсендә беленү.

**ПРОНЯ'НЧИТЬ** *сов.*— (берникадәр вакыт) бала карап үткәрү, бала карап тору.

**ПРОНЯ'НЧИТЬСЯ** *сов. разг.*—1. к. пронянчить; 2. (кемне дә булса) назлап, вакыт үткәрү, иркәләп вакыт үткәрү.

**ПРОНЯ'ТЬ** *сов. разг.*— нык тәэсир итү; *сначала он слушал музыку равнодушно, но потом и его проняло* — башта ул музыканы тыныч (дулкынланмыйча) тыңлады, аннан ул аңар да нык тәэсир итте. ◇ **Его ничем не проймёшь** — аны һичбер нәрсә белән җинә алмыйсың. **Меня так и проняло страхом** — мине курку басты, мин куркуга төштем.

**ПРОО'БРАЗ** *м. книж. торж.*— үрнәк, төп үрнәк, беренче үрнәк; *Советы, впервые родившиеся в 1905 году, явились прообразом Советской власти, созданной пролетариатом под руководством большевистской партии в 1917 году* — беренче тапкыр 1905 елны туган Советлар 1917 елны большевистик партия җитәкчелеге астында пролетариат тарафыннан төзелгән Совет властеның үрнәге булдылар.

**ПРООБРАЗОВА'ТЬ** *сов. книж. торж.*— үрнәге булып тору, беренче үрнәге булып тору.

**ПРООБРАЗО'ВЫВАТЬ** *несов. книж. торж.*— к. прообразовать.

**ПРООРА'ТЬ** I *сов. разг. фам.*—1. акырып җибәрү, кычкырып җибәрү, бакырып җибәрү; *вдруг проорал во всё горло* — кинәт бөтен көченә акырып җибәрде; 2. кычкырып (берникадәр вакытны) үткәрү, акырып (бакырып) үткәрү.

**ПРООРА'ТЬ** II *сов. обл.*—1. *(пропахать)* (буразна) сызып чыгу, сөреп чыгу; 2. сөреп (берникадәр вакытны) үткәрү.

**ПРОО'ХАТЬ** *сов. разг.*—1. *(сказать что-н., охнув)* ахылдап әйтеп кую; 2. ахылдап (берникадәр вакытны) үткәрү.

**ПРОПАГА'НДА** *ж. мн.* нет — пропаганда.

**ПРОПАГАНДИ'РОВАТЬ** *несов.*— пропагандалау.

**ПРОПАГАНДИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.*— пропагандалану.

**ПРОПАГАНДИ'СТ** *м.*— пропагандист, пропагандалаучы, пропаганда эшләре алып баручы.

**ПРОПАГАНДИ'СТСКИЙ** — пропаганда...-ы, пропагандист...-ы; пропагандистлар...-ы, пропагандистлык...-ы; *пропагандистская работа* — пропагандист эше, пропаганда эшләре; *пропагандистские кадры* — пропагандистлар кадрлары.

**ПРОПА'ДАТЬ** *сов. разг.*— (берникадәр вакыт) яву, төшү, явып тору; *целый день пропадал снег* — көн буе кар яуды, көн буе кар явып торды.

**ПРОПАДА'ТЬ** *несов.*— к. пропасть. ◇ **Где наше не пропадало!** *разг.*— ни булса, ул булыр! Тәвәккәл! каян килеп кая китмәгән! **Пропадай моя телега, все четыре колеса** *разг.*—1. ни булса, ул булыр! Тәвәккәл! 2. эш харап!

**ПРО'ПАДОМ: пропади пропадом!** *разг. неодобр.*— дөмеккере! җаның җәһәннәм астына киткере!

**ПРОПА'ЖА** *ж.*—1. к. пропасть; 2. *разг.* югалган әйбер.

**ПРОПА'ИВАТЬ** I *несов. спец.*— к. пропаять.

**ПРОПА'ИВАТЬ** II *несов.*— к. пропоить.

**ПРОПА'ИВАТЬСЯ** I *несов. страд. спец.*—

паять итеп чыгылу, кургаш коеп ябыштырылу.

**ПРОПА'ИВАТЬСЯ** II *несов. страд.*— эчереп бетерелү, эчүгә тотылып бетү (акча турында).

**ПРОПА'ЛЗЫВАТЬ** *несов.*— к. пропо́лзать.

**ПРОПА'ЛЗЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— к. проползаться.

**ПРОПА'ЛИВАТЬ** *несов. разг.*— к. пропалить I.

**ПРОПА'ЛИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— үтәли яндырылу, үтәли көйдерелү.

**ПРОПАЛИ'ТЬ** I *сов. разг.*—1. *(прожечь насквозь)* үтәли яндыру, үтәли көйдерү; яндырып тишеп чыгару; 2. өтеп (берникадәр вакытны) үткәрү; *всё утро пропалила кур* — бөтен иртәне тавыклар өтеп үткәрде.

**ПРОПАЛИ'ТЬ** II *сов. разг. устар.*— 1. *(выстрелить)* ату, атып җибәрү; 2. атып тору, атып (берникадәр вакытны) үткәрү; *весь день пропалили из пушек* — көн буе туплардан атып тордылар.

**ПРОПАЛО'Й** *обл. устар.*— к. пропащий.

**ПРОПА'ЛЫВАТЬ** *несов.*— к. прополоть.

**ПРОПА'ЛЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— утап чыгылу

**ПРОПА'РИВАТЬ** *несов.*— к. пропа́рить.

**ПРОПА'РИВАТЬСЯ** *несов.*—1. к. пропариться; 2. *страд.* пешекләнү.

**ПРОПА'РИТЬ** *сов.*— 1. (яхшы итеп) парлау, пешекләү; *пропарить овощи* — яшелчәләрне пешекләү; 2. пешекләп (берникадәр вакытны) үткәрү; *весь вечер пропарила овощи* — кич буе яшелчәләр пешекләп үткәрдем. ◇ Пропарить навоз *с.-х.*— тирес черетү.

**ПРОПАРИ'ТЬ** *сов.*— (берникадәр вакыт) һавада йөзү, һавада йөзеп йөрү, очып йөрү, (канат җилпемичә) очып йөрү.

**ПРОПА'РИТЬСЯ** *сов.*—1. парлану, чабыну; *докрасна пропариться в бане* — мунчада кызарганчы чабыну; 2. (берникадәр вакыт) чабыну, чабынып (берникадәр вакытны) үткәрү; *пропариться два часа* — ике сәгать буе чабыну.

**ПРОПА'РХИВАТЬ** *несов.*— к. пропорхнуть.

**ПРОПА'РЫВАТЬ** *несов.*— к. пропороть.

**ПРОПА'РЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*—1. тишелү, тишеп чыгарылу; 2. ертылу.

**ПРОПАСТИ'** *сов.*—1. (берникадәр вакыт) көтү көтү, көтү көтеп (берникадәр вакытны) үткәрү; *пропасти стадо до самых заморозков*—көтүне көзге кырау төшкәнче көтү; 2. *обл.* көтү көткәндә югалту; *пастух пропас овцу* — көтүче көтү көткәндә бер сарыкны югалткан.

**ПРОПАСТИ'НА** *ж. мн.* нет, *обл.*— үләксә, шакшы.

**ПРОПАСТИ'СЬ** *сов.*— (берникадәр вакыт) көтүдә йөрү.

**ПРОПАСТНО'Й** — бик начар, бернигә яраксыз.

**ПРО'ПАСТЬ** I *ж.*—1. упкын, төпсез чокыр; *на краю пропасти* — упкын кырыенда; 2. *перен. книж.* зур аерма; *между ними целая пропасть* — алар арасында бик зур аерма бар. ◇ **На краю пропасти** *перен.*— яр якасында, һәлакәт алдында. **Скатиться в пропасть** *перен.*— һәлакәткә барып җитү. **Пропасти на тебя нет!** *простореч. бран.*— дөмекмисең дә бит шунда! **Тьфу пропасть!** *разг.*— тфү, шайтан алгыры! тфү, кабахәт!

**ПРО'ПАСТЬ** II *ж. разг.*— бик күп; исәпсез-хисапсыз, хисапсыз күп; *народу было пропасть* — халык бик күп иде.

**ПРОПА'СТЬ** *сов.*—1. югалу, җуелу, юк булу, юкка чыгу; *книга пропала* — китап югалды; 2. ...-мый башлау, бетү; *голоса пропали* — тавышлар ишетелми башлады; *у них пропал смех* — алар көлми башладылар; *пропали горы* — таулар күренми башлады; 3. *(погибнуть)* югалу, һәлак булу; 4. бозылу, яраксыз хәлгә килү; *во время перехода по горам обувь совсем пропала* — тауларны кичкәндә аяк киемнәре бөтенләй яраксыз хәлгә килде; 5. әрәмгә китү, әрәм булу, югалу; *день пропал* — көнем югалды, көнем әрәмгә китте. ◇ **Пиши пропало** *разг.*— харап булды диген. **Пропади ты пропадом** *просторечи. бран.*— к. пропадом.

**ПРОПАХА'ТЬ** *сов.*—1. (буразна) яру, (буразна) ярып чыгу; *пропахать борозду* — буразна ярып чыгу; 2. сөрү, сөреп чыгу; *надо хорошенько пропахать* — яхшы гына сөреп чыгарга кирәк; *глубоко пропахать*— тирән сөрү; 3. (берникадәр вакыт) сөрү, сөреп (берникадәр вакытны) үткәрү; *пропахать весь день поле* — көн буе җир сөреп үткәрү.

**ПРОПА'ХИВАТЬ** I *несов.*— к. пропахать.

**ПРОПА'ХИВАТЬ** II *несов.*— к. пропахнуть.

**ПРОПА'ХИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— сөрелү, сөреп чыгылу.

**ПРОПА'ХНУТЬ** *сов.*—1. исе сеңү, исе сеңеп бетү; *шуба пропахла нафталином* — тунга нафталин исе сеңгән; 2. *разг.* исләнү, ис чыга башлау, ис керү, сасу; *мясо пропахло* — ит исләнгән.

**ПРОПАШНИ'К** *м. с.-х.*— пропашник (рәт араларын йомшарту өчен кулланыла торган сабан).

**ПРОПАШНО'Й, ПРОПА'ШНЫЙ** *с.-х.*— 1. сөрү...-ы, җир сөрү...-ы; *пропашные орудия* — җир сөрү кораллары; 2. сызма...; *пропашные культуры* — сызма культуралар.

**ПРОПА'ЩИЙ** *просторечи.*— ышанычсыз, өметсез; бетүгә йөз тоткан, бернигә дә яраксыз, төзәлми торган; *пропащий человек* — өметсез кеше (беткән кеше). ◇ **Пропащее дело** *просторечи.*— эш харап.

**ПРОПАЯ'ТЬ** *сов. спец.*—1. кургаш коеп ябыштыру, паять итеп чыгу; *пропаять носик чайника* — чәйнекнең борынын (яхшылап) паять итеп кую; 2. паять итеп (берникадәр вакытны) үткәрү; *пропаять ведро два часа* — ике сәгать вакытны чиләк паять итеп үткәрдем, чиләкне ике сәгать паять иттем.

**ПРОПЕДЕ'ВТИКА** *ж. мн.* нет, *книж.*— пропедевтика (берәр нәрсә турында башлангыч белемнәр; нинди дә булса бер фәнгә кереш).

**ПРОПЕДЕВТИ'ЧЕСКИЙ** *книж.*— пропедевтик, башлангыч, кереш; *пропедевтический курс* — пропедевтик курс.

**ПРОПЕКА'ТЬ** *несов.*— к. пропечь.

**ПРОПЕКА'ТЬСЯ** *несов.*—1. к. пропечься; 2. *страд.* пешереп җиткерелү.

**ПРОПЕ'ЛЛЕР** *м.*— пропеллер.

**ПРОПЕРЕ'ТЬ** *сов. простореч. вульг.*— 1. тартып чыгару, этеп чыгару; кысрыклап китерү; *проперет сундук в дверь* — сандыкны ишектән тартып чыгару; *стоявшие сзади пропёрли его к выходу* — артта торучылар аны ишеккә таба кысрыклап китерделәр; 2. җәяү бару; *проперет до вокзала* — вокзалга кадәр җәяү бару.

**ПРОПЕРЕ'ТЬСЯ** *сов. простореч. вульг.*— 1. кысылып чыгу, кысыла-кысыла чыгу; *еле пропёрся через двери* — ишектән көчкә генә кысыла-кысыла чыктым; 2. җәяү бару; *пропёрся десять километров* — ун чакрым җәяү бардым.

**ПРОПЕ'РЧИВАТЬ** *несов. разг.*— к. проперчить.

**ПРОПЕ'РЧИВАТЬСЯ** *несов. разг.*—1. к. проперчиться; 2. *страд.* кирәгеннән артык борычлану, кирәгеннән артык борыч сибелү, кирәгеннән артык борыч салыну.

**ПРОПЕ'РЧИТЬ** *сов. разг.*— кирәгеннән артык борычлау, кирәгеннән артык борыч сибү, кирәгеннән артык борыч салу.

**ПРОПЕ'РЧИТЬСЯ** *сов. разг.*— борыч тәме керү, борыч тәме сеңү.

**ПРОПЕ'ТЬ** *сов.*—1. җырлау, җырлап алу; *пропеть романс* — романс җырлау; 2. (берникадәр вакыт) җырлау; *пропел на этой сцене четыре сезона* — бу сәхнәдә дүрт сезон җырлады. ◇ **Пропеть голос** *разг.*— күп җырлап (җырлый-җырлый) тавышны бетерү. **Пропел петух** — әтәч кычкырды. **Пропел соловей** — сандугач сайрап алды.

**ПРОПЕЧА'ТАТЬ** *сов. разг.*—1. *простореч.* язып чыгу, бастырып чыгару (кемнең дә булса кимчелекләрен); *пропечатать кого-н. в газете* — берәр кеше турында газетада язып чыгу, газетага бастырып чыгару; 2. (берникадәр вакыт) басу, басып (берникадәр вакытны) үткәрү; *весь день пропечатала на машинке* — көн буе машинкада бастым; 3. к. печатать 1.

**ПРОПЕЧА'ТЫВАТЬ** *несов. разг.*— к. пропечатать 1.

**ПРОПЕЧА'ТЫВАТЬСЯ** *несов. страд. простореч.*— матбугатта фаш ителү.

**ПРОПЕ'ЧЬ** *сов.*—1. пешереп җиткерү, пешүен китерү; *пропечь хлеб* — икмәкне пешереп җиткерү; 2. *разг.* бик нык кыздыру; *пропечь спину на солнце* — арканы кояшта бик нык кыздыру; 3. (берникадәр вакыт) пешерү, пешереп (берникадәр вакытны) үткәрү; *пропечь блины до вечера* — кичкә кадәр белен пешерү.

**ПРОПЕ'ЧЬСЯ** *сов.*—1. пешеп җитү, пешүе килү; *хлеб не пропёкся* — икмәк пешеп җитмәгән; 2. *разг.* бик нык кызыну; *пропечься на солнце* — кояшта бик нык кызыну.

**ПРОПИВА'ТЬ** *несов.*— к. пропить.

**ПРОПИВА'ТЬСЯ** *несов.*—1. *разг.* к. пропиться; 2. *страд.* эчүгә тотып бетерелү.

**ПРОПИ'Л** *м. спец.*—1. *только ед.* к. пропилить 1; 2. пычкы белән киселгән урын.

**ПРОПИ'ЛИВАТЬ** *несов.*— к. пропилить.

**ПРОПИ'ЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— пычкы белән киселү.

**ПРОПИЛИ'КАТЬ** *сов. разг. пренебр.*— 1. чыелдатып алу; *пропиликал на скрипке* — скрипкада чыелдатып алды; 2. (берникадәр вакыт) чыелдату, чыелдатып тору, чыелдатып (берникадәр вакытны) үткәрү; *пропиликать целый вечер на скрипке* — кич буе скрипкада чыелдатты.

**ПРОПИЛИ'ТЬ** *сов.*— 1. пычкы белән кисү; *пропилить доску до середины* — тактаны уртасына кадәр пычкы белән кисү; 2. пычкы белән кисеп ясау; *пропилить в двери окошечко* — пычкы белән кисеп ишеккә кечкенә генә тәрәзә ясау; 3. (берникадәр вакыт) кисү, кисеп (берникадәр вакытны) үткәрү; *целый день пропилили дрова* — көн буе утын кистек.

**ПРОПИНА'ТЬ** *несов. книж. устар.*— к. пропять.

**ПРОПИРА'ТЬ** *несов. простореч. вульг.*— к. проперeть.

**ПРОПИРА'ТЬСЯ** *несов. простореч. вульг.*— 1. к. проперeться; 2. *страд.* тартып чыгарылу, этеп чыгарылу; кысрыклап китерелү.

**ПРОПИСА'ТЬ** *сов.* — 1. яздыру, теркәү, пропискага кертү; *прописать нового жильца* — яңа килгән кешене яздыру; 2. язу, язып бирү; *врач прописал хину* — врач хин язды; 3. (берникадәр вакыт) язу, язып (берникадәр вакытны) үткәрү, язып утыру; *я статью прописал всю ночь* — мин мәкаләне төн буе язып утырдым; 4. *простореч.* к. пропечатать 1; 5. *простореч. фам. устар.* кирәкне бирү, эләгү; *смотри, тебе за это пропишут* — кара, моның өчен сиңа эләгер (кирәгеңне бирерләр). ◇ **Прописать ижицу** *устар., теперь шутл.*— кирәкне бирү, кыйнау; шелтәләү.

**ПРОПИСА'ТЬСЯ** *сов.*— пропискага керү, язылу, теркәлү, (тору урының паспортта күрсәтеп, рәсми рәвештә регистрацияләнү).

**ПРОПИ'СКА,** *ж.*— 1. *только ед. (действие)* к. прописать 1, прописаться; 2. *разг.* прописка (торак урының күрсәткән язу).

**ПРОПИСНО'Й** — 1. *( о буквах)* баш...; *прописная буква* — баш хәреф; 2. *канц.* язылу...-ы, теркәлү...-ы; *прописной листок* — теркәлү кәгазе. ◇ **Прописная истина** *неодобр.*— ап-ачык, шаблон булып киткән (һәркемгә дә билгеле булган) хакыйкать. **Прописная мораль** *неодобр.* — һәркемгә дә билгеле булган мораль.

**ПРОПИ'СЫВАТЬ** *несов.*— к. прописать.

**ПРОПИ'СЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. прописаться; 2. *страд.* яздырылу, теркәлү; язып бирелү.

**ПРО'ПИСЬ** *ж.*— 1. дөрес язу үрнәге, матур язу үрнәге; *учиться писать по прописям* — матур язу үрнәкләре буенча язарга өйрәнү; 2. *спец.* кулдан язу; курсив. ◇ **Написать сумму прописью** — суммасын сүзләр белән язу (цифр белән түгел).

**ПРОПИТА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *устар. офиц.*— 1. *(действие)* к. пропитать I; 2. *(пища)* азык.

**ПРОПИТА'ТЬ** I *сов. устар.*— туендыру, азык бирү.

**ПРОПИТА'ТЬ** II *сов.*— 1. сеңдерү; *пропитать тряпку маслом* — чүпрәккә май сеңдерү; 2. сеңү; *одежду пропитал запах нафталина* — киемгә нафталин исе сеңгән; 3. *перен. (пронизать)* сугару. ◇ **Сырость пропитала стены** — стеналар дымланган, стеналар юешләнгән.

**ПРОПИТА'ТЬСЯ** *сов.*— 1. сеңү; *куртка пропиталась машинным маслом* — курткага машина мае сеңгән; 2. *перен.* сугарылу, *пропитаться новыми идеями* — яна идеяләр белән сугарылу.

**ПРОПИ'ТОЧНЫЙ** *спец.*— 1. чылату...-ы; *пропиточный чан* — чылату чаны; 2. сеңдерелә торган; *пропиточный раствор* — сеңдерелә торган эремә.

**ПРОПИ'ТЫВАТЬ** *несов.*— к. пропитать.

**ПРОПИ'ТЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. пропитаться; 2. *страд.* сеңдерелү; сугарылу.

**ПРОПИ'ТЬ** *сов.*— 1. эчеп бетерү, эчүгә тотып бетерү; *пропить все деньги* — барлык акчаны эчүгә тотып бетерү; 2. (берникадәр вакыт) эчү; *пропил всю ночь* —төн буе эчте. ◇ **Пропить голос** — күп эчеп (эчә-эчә) тавышны бетерү. **Пропить талант** — күп эчеп талантын югалту, эчә-эчә талантын югалту.

**ПРОПИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — (барлык акчасын) эчеп бетерү, эчә-эчә бөлгенлеккә төшү.

**ПРОПИХА'ТЬ** *сов. разг.*— этkәләп-төрткәләп кертү, төрткәләп кертү.

**ПРОПИХА'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.*— этkәләп-төрткәләп үтү (керү, чыгу), ерып керү (чыгу).

**ПРОПИ'ХИВАТЬ** *несов. разг.*— к. пропихнуть, пропихать.

**ПРОПИ'ХИВАТЬСЯ** *несов. разг. фам.*— к. пропихаться.

**ПРОПИХНУ'ТЬ** *сов. разг.*— этеп кертү, төртеп кертү.

**ПРОПИХНУ'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.*— этеп-төртеп үтү (керү, чыгу).

**ПРОПИЩА'ТЬ** *сов.*— 1. чыелдап кую, чыелдап җибәрү, чинап кую, чинап җибәрү; *пропищала мышь* — тычкан чыелдап куйды; 2. (берникадәр вакыт) чыелдау, чинау, чыелдап тору, чинап тору.

**ПРОПЛА'ВАТЬ** *сов.*— (берникадәр вакыт) йөзү, йөзеп йөрү.

**ПРОПЛА'ВИТЬ** *сов.*— 1. *тех.* эретү, эретеп чыгару; *проплавить тысячу тонн металла* — мең тонна металл эретү; 2. (берникадәр вакыт) эретү, эретеп (берникадәр вакыт) үткәрү.

**ПРОПЛА'ВЛИВАТЬ** *несов.*— к. проплавить.

**ПРОПЛА'ВЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— эретелү, эретеп чыгарылу.

**ПРОПЛАВЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. проплавить.

**ПРОПЛАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— к. проплавливаться.

**ПРОПЛА'КАТЬ** *сов.*— (берникадәр вакыт) елау, елап тору, елап чыгу; *проплакать всю ночь* — төн буе елап чыгу. ◇ **Проплакать глаза** *разг.*— күп елап күзләрне бозу, елый-елый күзләрне бозып бетерү (шешенеп бетү).

**ПРОПЛА'КАТЬСЯ** *сов. разг.*— елап күңелне бушату.

**ПРОПЛАКНУ'ТЬ** *сов. разг. фам. редко* — елаган тавыш белән әйтү, елаган тавыш белән әйтеп кую.

**ПРОПЛЕВА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. *фам. (заплевать)* төкереп пычрату, төкереп пычратып бетерү; 2. (берникадәр вакыт) төкерү, төкереп тору; төкеренү.

**ПРОПЛЕ'СНЕВЕТЬ, ПРОПЛЕ'СНЕТЬ** *сов.*— күгәрү, күгәреп бетү.

**ПРОПЛЕСТИ'** *сов.*— 1. кушып үрү; *проплести косу лентами* — толымга тасма кушып үрү; 2. (берникадәр вакыт) үрү, үреп (берникадәр вакытны) үткәрү; *проплёл сеть два дня* — ике көн буе ятьмә үрдем.

**ПРОПЛЕСТИ'СЬ** *сов. разг.*— әкрен генә үтеп китү, әкрен генә узып китү.

**ПРОПЛЕТА'ТЬ** *несов*— к. проплести.

**ПРОПЛЕТА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— кушып үрелү.

**ПРОПЛУТА'ТЬ** *сов. разг.*— (берникадәр вакыт) адашып йөрү; *проплутать весь день по лесу* — көн буе урманда адашып йөрү.

**ПРОПЛЫ'В** *м. спорт.*— йөзү, йөзү ярышы; *проплыв на один километр* — бер километрга йөзү ярышы.

**ПРОПЛЫВА'ТЬ** *несов.*— к. проплыть.

**ПРОПЛЫ'ТЬ** *сов.*— 1. йөзеп үтү; йөзеп барып житү; *проплыть полкилометра* — ярты километр йөзеп үтү; *проплыть до середины реки* — елганың уртасына йөзеп барып житү; 2. бару; *проплыть на пароходе сто километров* — йөз километр пароходта бару; 3. янынпан (йөзеп) үтеп китү, йөзеп үтү, йөзеп узу; *мы проплыли маяк* — без маякны (йөзеп) уздык; 4. (берникадәр вакыт) утырып йөрү (көймәгә, пароходка һ. б.); *проплыли двое суток под парусом* — ике тәүлек буена җилкәнле көймәдә йөрдек; 5. *перен. разг. шутл.* эре генә үтеп китү, кукраеп үтеп китү; 6. *перен.* үтеп китү; *перед глазами проплыли воспоминания детства* — балачак истәлекләре күз алдыннан үтеп киттеләр.

**ПРОПЛЯСА'ТЬ** *сов.*— 1. биеп алу; 2. (берникадәр вакыт) бию, биеп (берникадәр вакытны) үткәрү; *проплясала весь вечер* — кич буе биеде, бөтен кичен биеп үткәрде.

**ПРОПЛЯ'СЫВАТЬ** *несов.*— к. проплясать.

**ПРОПНУ'ТЬ** *сов. разг. фам.*— к. проткнуть.

**ПРОПОВЕ'ДАТЬ** *сов.* и *несов. разг устар.*— к. проповедовать.

**ПРОПОВЕ'ДНИК** *м.*, **ПРОПОВЕ'ДНИЦА** *ж. книж.*— 1. вәгазьләүче, вәгазь сөйләүче; 2. дингә өндәүче, дин таратучы; *проповедник христианства* — христиан динен таратучы; 3. *перен.* таратучы; *проповедник новой теории* — яңа теория таратучы.

**ПРОПОВЕ'ДНИЧЕСКИЙ** *книж.*— вәгазьләүче...-ы, вәгазьләүчегә хас; *проповеднический тон* — вәгазьләүчегә хас тон.

**ПРОПОВЕ'ДОВАТЬ, ПРОПОВЕ'ДЫВАТЬ** *несов.*— 1. *рел.* дин тарату, дингә өндәү; 2. *рел.* вәгазьләү; 3. *перен.* тарату, өндәү.

**ПРО'ПОВЕДЬ** *ж.*— 1. *рел.* вәгазь; 2. *перен разг. (наставление, нравоучение)* үгет, нәсихәт, вәгазь; 3. *перен.* тарату, өндәү; *проповедь новой теории* — яңа теория тарату; *проповедь новых взглядов* — яңа карашлар тарату.

**ПРОПОЗИ'ЦИЯ** *ж. книж.*— җөмлә.

**ПРОПОИ'ТЬ** *сов.*— 1. *простореч.* эчереп бетерү, эчерүгә тотып бетерү; *пропоил сто рублей* — йөз сум акчасын эчереп бетергән; 2. (берникадәр вакыт) эчерү; *пропоил молоком телёнка полгода* — бозауга ярты ел сөт эчердем.

**ПРОПО'ЙНЫЙ** *простореч.*— 1. эчәргә билгеләнгән, эчүгә тотылырга тиеш булган, эчәргә куелган; *пропойные деньги* — эчәргә куелган акча; 2. эчкече кеше...-ы, эчкече...-ы; *пропойный голос* — эчкече кеше тавышы; *пропойный вид* — эчкече кеше кыяфәте.

**ПРОПО'ЙЦА** *м. простореч. презрит.*— эчкече, исерек баш, эчүче.

**ПРОПОЛА'СКИВАТЬ** *несов.*— к. прополоскать.

**ПРОПОЛА'СКИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— чайкалу, чайкап алыну.

**ПРОПО'ЛЗАТЬ** *сов.*— (берникадәр вакыт) шуышып йөрү, үрмәләп йөрү.

**ПРОПОЛЗА'ТЬ** *несов.*— к. проползти.

**ПРОПОЛЗА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— шуышып үтелү, үрмәләп үтелү.

**ПРОПОЛЗТИ'** *сов.*— 1. шуышып үтү, үрмәләп үтү; *проползти по земле* — җирдән шуышып үтү; 2. *разг.* үрмәләп керү, шуышып керү; керү; *в комнату проползла змея* — бүлмәгә елан кергән.

**ПРО'ПОЛИС** *м. с.-х.*— прополис, умарта корты җилеме, тома балавыз.

**ПРОПО'ЛКА** *ж. мн.* нет, *с.-х.*— утау, чүп утау.

**ПРОПОЛОСКА'ТЬ** *сов.* — 1. чайкау, чайкап алу; *прополоскать рот* — авызны чайкау; 2. (берникадәр вакыт) чайкау, чайкап (берникадәр вакытны) үткәрү; *прополоскала весь вечер бельё на речке* — бөтен кичен елгада кер чайкап үткәрде.

**ПРОПОЛОСКА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— (чупырдашып су) коену, су керү; *ребята целый день прополоскались в реке* — балалар көн буе чупырдашып су коендылар.

**ПРОПОЛО'ТЬ** *сов.*— 1. утап чыгу; *прополоть грядку* — түтәлне утап чыгу; 2. (берникадәр вакыт) утау, утап (берникадәр вакытны) үткәрү.

**ПРОПОРО'ТЬ** *сов.*— 1. тишү, тишеп чыгару; *пропороть живот* — эчне тишү; 2. *простореч. (разорвать)* ерту, ертып чыгару; 3. *разг.* (берникадәр вакыт) сүтү, сүтеп (берникадәр вакытны) үткәрү; *весь вечер пропорола старую шубу* — бөтен кичемне иске тун сүтеп үткәрдем. ◇ **Целый вечер пропорол глупости (чепуху, ерунду)** *просторeч.*— бөтен кичне юк-бар нәрсәләр сөйләп үткәрде.

**ПРОПОРХНУ'ТЬ** *сов.*— пырылдап очып китү, пырылдап очып үтеп китү.

**ПРОПОРЦИОНА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — пропорциональлек, пропорциональ булу.

**ПРОПОРЦИОНА'ЛЬНЫЙ** *книж.* — пропорциональ.

**ПРОПО'РЦИЯ** *ж. книж.* — пропорция.

**ПРОПОТЕ'ТЬ** *сов.* — 1. шабыр тиргә бату, бик нык тирләү; *больной пропотел ночью* — авыру төнлә бик нык тирләде; 2. *разг.* тир белән юешләнү, тир сеңү; *одежда пропотела* — киемгә тир сеңгән; 3. *перен. разг. фам.* (берникадәр вакыт) җәфалану, азаплану.

**ПРОПРЕВА'ТЬ** *несов.* — к. пропреть.

**ПРОПРЕ'ТЬ** *сов.* — 1. *кулин.* пешеп җитү, парланып пешеп җитү; *репа не пропрела* — шалкан пешеп җитмәгән; 2. *просторeч.* к. пропотеть; 3. *разг. шутл.* (берникадәр вакыт) бәхәсләшү, бәхәсләшеп үткәрү, сүз көрәштереп үткәрү; *пропрели целый час* — бер сәгать вакытны бәхәсләшеп үткәрдек.

**ПРОПРЯ'СТЬ** *сов.* — (берникадәр вакыт) (җеп) эрләү; *пропряла всю неделю* — атна буе җеп эрләдем.

**ПРО'ПУСК** *м.* — 1. *только ед.* к. пропустить 1, 2, 3, 4, 5; 2. пропуск; *входить по пропускам* — пропуск белән керү; 3. буш урын; *печатать с пропусками* — буш урыннар калдырып басу; 4. *воен.* к. пароль.

**ПРОПУСКА'ТЬ** *несов.* — к. пропустить.

**ПРОПУСКА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. үткәрелү; 2. юл бирелү, уздырылу; 3. кертелү, җибәрелү; 4. төшереп калдырылу; 5. калдырылу.

**ПРОПУСКНИ'К** *м.* — пропускник, санпропускник.

**ПРОПУСКНО'Й** — пропуск...-ы, пропусклар...-ы; *пропускная система* — пропусклар системасы. ◇ **Пропускная бумага** — киптергеч (кәгазь). **Пропускная способность** *спец.* —үткәрү мөмкинлеге.

**ПРОПУСТИ'ТЬ** *сов.* — 1. үткәрү; *занавеска не пропускает света* — пәрдә яктылыкны үткәрми; 2. юл бирү, уздыру, кертү, үткәрү, үткәреп җибәрү; *пропустите женщину с ребёнком* — балалы хатынны үткәрегез; 3. керергә рөхсәт итү, кертү, җибәрү; *пропустить в парк* — паркка кертү; 4. төшереп калдыру; *пропустить слово* — сүз төшереп калдыру; 5. калдыру; *пропустить два урока* — ике дәресне калдыру; 6. *просторeч.* җибәрү, салу, эчү; *пропустить по рюмочке* — берәр рюмка салу (эчү). ◇ **Пропустить мимо ушей** — колагына да элмәү. **Пропустить удобный случай** — уңайлы очрактан файдаланмый калу.

**ПРОПЫЛИ'ТЬ** *сов.* — тузанландыру, тузанга батыру.

**ПРОПЫЛИ'ТЬСЯ** *сов.*— тузанлану, тузанга бату.

**ПРОПЫХТЕ'ТЬ** *сов.* — 1. ухылдап кую; 2. (берникадәр вакытны) ухылдап үткәрү; (берникадәр вакыт) мышнау, мышнап үткәрү; 3. *разг.* уфылдап узып китү; уф-уф итеп узып китү; *вдали пропыхтел паро-*

*воз* — еракка уф-уф итеп паровоз узып китте.

**ПРОПЯ'ТИТЬ** *сов.* — (берникадәр) чигендерү.

**ПРОПЯ'ТИТЬСЯ** *сов.* — (берникадәр) чигенү, артка чигү.

**ПРОПЯ'ТЬ** *сов. книж. устар.* — к. распять.

**ПРОПЯ'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. пропятить.

**ПРОПЯ'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. пропятиться; 2. *страд.* чигендерелү.

**ПРОРА'Б** *м.* — прораб (төзү эшләрендә турыдан-туры житәкчелек итүче техник яки инженер).

**ПРОРАБА'ТЫВАТЬ** *несов.* — к. проработать.

**ПРОРАБА'ТЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — җентекләп өйрәнелү.

**ПРОРАБО'ТАТЬ** *сов.* — 1. (берникадәр вакыт) эшләү, эшләп (берникадәр вакытны) үткәрү; *проработал на заводе три года* — өч ел заводта эшләдем; 2. җентекләп өйрәнү, җентекләп тикшерү; *проработать вопрос* — мәсьәләне җентекләп өйрәнү; *проработать план работ* — эшләрнең планын җентекләп тикшерү; 3. *разг. шутл.* бик нык пешерү, каты тәнкыйть итү; *его проработали на собрании* — аны җыелышта бик нык пешергәннәр.

**ПРОРАСТА'ТЬ** *несов.* — к. прорасти.

**ПРОРАСТИ'** *сов.* — 1. шыту, үрү; *картошка проросла* — бәрәңге үргән; 2. үсеп чыгу, шытып чыгу, тишелеп чыгу; *трава проросла* — үлән үсеп чыккан; 3. (берникадәр вакыт) үсү; *кустик ещё прорастёт года два* — куакчык тагы бер-ике ел үсәр әле.

**ПРОРАСТИ'ТЬ** *сов.* — үрдерү, шыттыру.

**ПРОРА'ЩИВАТЬ** *несов.* — к. прорастить.

**ПРОРА'ЩИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — үрдерелү, шыттырылу.

**ПРО'РВА** *ж. простореч.* — 1. бик күп, очсыз-кырыйсыз; *истратил прорву денег* — бик күп акча тоттым; 2. *неодобр.* гуж, бирән; *экая прорва!* — бу нинди бирән бу! бу нинди гуж бу! 3. *обл.* чоңгыл.

**ПРОРВА'ТЬ** *сов.* — 1. ерту, тишү; *прорвать чулок* — оекны тишү; 2. ерү; *прорвало плотину* — буаны су ерган; 3. *воен.* өзү; *прорвать фронт противника* — дошман фронтын өзү; 4. ерткалап (берникадәр вакытны) үткәрү. ◇ Его **прорвало** *безл. простореч фам.* — түзә алмады, ачуы чыкты, түземлеген югалтты.

**ПРОРВА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. тишелү, ертылу; *прорвался платок* — яулык ертылган; 2. ерылу; *прорвалась плотина* — буа ерылган; 3. *воен.* өзелү; *фронт прорвался* — фронт өзелгән; 4. үтү; *прорваться сквозь расположение противника* — дошман урнашкан җирдән үтү.

**ПРОРЕВЕ'ТЬ** *сов.* — 1. үкереп җибәрү, үкереп кую; *проревел лев* — арслан үкереп куйды; 2. *просторәч.* (берникадәр вакыт) үкерү, елау, елап тору; *проревел целый час* — бер сәгать буена елады, бер сәгать елап торды.

**ПРОРЕДИ'ТЬ** *сов. с.-х.* — сирәкләү, сирәгәйтү, сирәгәйтеп чыгу.

**ПРОРЕ'ЖИВАТЬ** *несов. с.-х.* — к. проредить.

**ПРОРЕ'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд. с.-х.* — сирәгәйтелү, сирәкләндерелү, сирәгәйтеп чыгылу.

**ПОРЕ'З** *м.* — 1. *только ед. (действие)* к. прорезать 1, 2; 2. киселгән урын, уеп алынган урын; уем, уентык.

**ПРОРЕ'ЗАТЬ** *сов.* — 1. үтәли кисеп чыгару, тишеп чыгару; *прорезать насквозь подошву* — олтанны тишеп чыгару; 2. ую; *прорезать у рубахи ворот* — күлмәкнең якасын ую; 3. *перен.* аркылы үтү, салыну; *железнодорожный путь прорезал степь* — дала аркылы тимер юл салынган; 4. (берникадәр вакыт) кисү, кисеп (берникадәр вакытны) үткәрү.

**ПРОРЕЗА'ТЬ** *несов.* — к. прорéзать.

**ПРОРЕ'ЗАТЬСЯ** *сов.* — 1. *(о зубах)* ярып чыгу, чыгу; 2. *перен. разг. (пробиться)* ерып чыгу.

**ПРОРЕЗА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. прорéзаться; 2. *страд.* үтәли кисеп чыгарылу; уелу.

**ПРОРЕЗИ'НИВАТЬ** *несов. тех.* — резина сеңдерү, резиналау.

**ПРОРЕЗИ'НИВАТЬСЯ** *несов. тех.* — 1. к. прорезиниться; 2. *страд.* резина сеңдерелү.

**ПРОРЕЗИ'НИТЬ** *сов. тех.* — к. прорезинивать.

**ПРОРЕЗИ'НИТЬСЯ** *сов. тех.* — резина сеңү.

**ПРОРЕЗНО'Й** — 1. *порт.* уеп ясалган, кисеп ясалган; *прорезной карман* — кисеп ясалган кесә; 2. *спец.* чокып ясалган, үтәли кисеп ясалган; киртләп ясалган; *прорезной штемпель* — кисеп ясалган штемпель.

**ПРОРЕ'ЗЫВАТЬ** *несов.* — к. прорéзать.

**ПРОРЕ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. прорéзаться.

**ПРО'РЕЗЬ** *ж.* — тишек, ерык, уентык; тишем.

**ПРОРЕКА'ТЬ** *несов. книж. устар., теперь ирон.* — к. прорицать.

**ПРОРЕ'КТОР** *м.* — проректор, ректор ярдәмчесе.

**ПРОРЕ'ХА** *ж.* — 1. ертык, тишек; *мешок с прорехой* — тишек капчык; 2. *перен. (недостаток)* җитешсезлек.

**ПРОРЕЦЕНЗИ'РОВАТЬ** *сов.* — рецензияләү, рецензияләп чыгу.

**ПРОРЕ'ЧЬ** *сов. книж. устар., теперь ирон.* — к. прорицать.

**ПРОРЖАВЕ'ЛЫЙ** *простореч.* — тутыгып беткән, үтәли тутыккан, тутыгып тишелгән, күгәргән, күгәреп беткән.

**ПРОРЖА'ВЕТЬ** *сов.* — үтәли тутыгу, тутыгып бетү, тутыгып тишелү, күгәреп бетү.

**ПРОРЖА'ТЬ** *сов.* — 1. кешнәү, кешнәп кую; *вдали проржала лошадь* — еракта ат кешнәде; 2. (берникадәр вакыт) кешнәү, кешнәп чыгу; *целую ночь проржала матка, звала жеребёнка* — бия колынын чакырып төн буе кешнәп чыкты.

**ПРОРИСОВА'ТЬ** *сов.* — 1. *спец.* ачыграк итеп сызып чыгу (рәсемне); 2. (берника-

дәр вакыт) рәсем ясау, рәсем ясап тору, рәсем ясап (берникадәр вакытны) үткәрү; *прорисовать целый день* — көн буе рәсем ясау.

**ПРОРИСОВА'ТЬСЯ** *сов. спец.* — ачык итеп беленеп тору (рәсемдәге сызыклар, контур турында).

**ПРОРИСО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. прорисовать.

**ПРОРИСО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. прорисоваться; 2. *страд.* ачыграк итеп сызып чыгылу (рәсем турында).

**ПРОРИЦА'НИЕ** *ср. книж. устар.* — 1. *только ед. (действие)* к. прорицать; 2. *(предсказание, пророчество)* алдан бирелгән хәбәр.

**ПРОРИЦА'ТЕЛЬ** *м.*, **ПРОРИЦА'ТЕЛЬНИЦА** *ж. книж. устар.* — киләчәктән хәбәр биреп торучы, киләчәктән хәбәр бирүче.

**ПРОРИЦА'ТЬ** *несов. книж. устар.* — киләчәктән хәбәр бирү, алдан хәбәр бирү.

**ПРОРО'К** *м.* — 1. пәйгамбәр; 2. к. прорицатель.

**ПРОРОНИ'ТЬ** *сов.* — 1. *обл. (уронить нечаянно)* төшерү, төшереп җибәрү; 2. әйтү, мычкындыру; *не проронить ни слова* — бер генә сүз дә әйтмәү.

**ПРОРО'СТ** *м. мн.* нет, *спец.* — к. прорасти.

**ПРО'РОСТЬ** *ж. спец.* — 1. катлам (агачта кыек яки аркылы үтә торган катлам; ит арасындагы май катламы яки май арасындагы ит катламы); 2. тамыр (карбызның, төрле җимешләрнең эчендә була торган тамыр); 3 *(нарост на стволе дерева)* оры.

**ПРОРО'ЧЕСКИЙ** *книж.* — 1. пәйгамбәр...-ы, пәйгамбәрләр...-ы; *пророческое одеяние* — пәйгамбәрләр киеме; 2. алдан күреп бирелгән; *пророческий совет* — алдан күреп бирелгән киңәш; 3. дөрес; *его слова оказались пророческими* — аның сүзләре дөрес булып чыкты.

**ПРОРО'ЧЕСТВО** *ср. книж.* — 1. *рел.* пәйгамбәрлек итү; 2. к. прорицать.

**ПРОРО'ЧЕСТВОВАТЬ** *несов. книж.* — 1. *церк.* пәйгамбәрлек итү; 2. *чаще ирон. (предсказывать)* алдан әйтеп тору, киләчәктән хәбәр биреп тору, киләчәктән хәбәр бирү.

**ПРОРО'ЧИТЬ** *несов.* — киләчәктән хәбәр биреп тору, алдан хәбәр бирү, алдан әйтеп тору, алдан кычкырып тору.

**ПРОРО'ЧИЦА** *ж.* — к. пророк.

**ПРОРУБА'ТЬ** *несов.* — к. прорубить.

**ПРОРУБА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. прорубиться; 2. *страд.* уелу, уеп ясалу, тишеп ясалу.

**ПРОРУБИ'ТЬ** *сов.* — 1. ую, уеп ясау; *прорубить окно* — тәрәзә ую; 2. кисү, салу; *прорубить просеку* — урман межасы кисү.

**ПРОРУБИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. агачларны кисеп ерып чыгу; *прорубиться сквозь чащу* — агачларны кисеп куелыкны ерып чыгу; 2. (берникадәр вакыт) кисешү, сугышу, сугышып (берникадәр вакытны) үткәрү; *прорубиться с врагом до вечера* — дошман белән кичкә кадәр сугышу. ◇ **Конница прорубилась сквозь ряды неприятеля** — атлы гаскәр дошман сафларын кырып үтте.

**ПРО'РУБЬ** *ж.* — бәке.

**ПРОРУ'ХА** *ж. обл.* — хата, ялгышлык. ◇ **И на старуху бывает проруха** — ат дүрт аяклы булса да абына.

**ПРОРЫ'В** *м.* — 1. *(действие)* к. прорвать 2, 3; прорваться 2, 3, 4; 2. ерма, су ерган урын; *заделать прорыв в плотине* — буаның су ерган урынын төзәтү; 3. *перен.* өзеклек, прорыв; *ликвидировать прорыв* — өзеклекне бетерү.

**ПРОРЫВА'ТЬ** I *несов.* — к. прорвать.

**ПРОРЫВА'ТЬ** II *несов.* — к. прорыть.

**ПРОРЫВА'ТЬСЯ** I *несов.* — 1. к. прорваться; 2. *страд.* ертылу, тишелү; ерылу; өзелү.

**ПРОРЫВА'ТЬСЯ** II *несов.* —1. к. прорыться 1; 2. *страд.* казылу, казып чыгылу; сирәкләндерелү, сирәгәйтелү.

**ПРОРЫ'ВЩИК** *м. пренебр.* — эштә өзеклек ясаучы, прорывчы.

**ПРОРЫСИ'ТЬ** *сов.* — юртып үтеп китү.

**ПРОРЫ'СКАТЬ** *сов.* — иснәнеп эзләп йөрү, иснәнеп йөрү, эзләнеп йөрү.

**ПРОРЫ'ТЬ** *сов.* — 1. казу, казып чыгу; *прорыть канаву* — канау казу; 2. *с.-х.* к. проредить; 3. (берникадәр вакыт) казу, казып (берникадәр вакытны) үткәрү; *яму прорыли целый час* — чокырны бер сәгать казыдык.

**ПРОРЫ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. казып чыгу, казый-казый чыгу; *крот прорылся на поверхность земли* — сукыр тычкан казып җир өстенә чыккан; 2. (берникадәр вакыт) актарыну, казыну, актарынып (берникадәр вакытны) үткәрү, актарып (берникадәр вакытны) үткәрү; *старуха целый час прорылась у себя в сундуке* — карчык бер сәгать вакытны сандыгын актарып үткәрде.

**ПРОРЫЧА'ТЬ** *сов.* — 1. ырылдап кую, үкереп кую; *прорычал тигр* — юлбарыс үкереп куйды; *прорычала собака* — эт ырылдап куйды; 2. (берникадәр вакыт) ырылдау, үкерү, акыру, ырылдап чыгу, үкереп чыгу; *всю ночь прорычала собака* — эт төн буе ырылдап чыкты.

**ПРОСАДИ'ТЬ** *сов. простореч.* — 1. тотып бетерү, таратып бетерү; *просадить все деньги* — бөтен акчаны тотып бетерү; 2. *(проколоть)* чәнчү, чәнчеп тишү; 3. *обл.* к. просажать.

**ПРОСА'ДКА** *ж. мн.* нет, *спец.* — 1. к. просесть 1; 2. *спец.* утыру, басылу, иңү; *просадка железнодорожного полотна* — тимер юл полотносының утыруы.

**ПРОСАЖА'ТЬ** *сов. разг.* — (берникадәр вакыт) утырту; утыртып (берникадәр вакытны) үткәрү; *весь день просажала картофель* — көн буе бәрәңге утырттым.

**ПРОСА'ЖИВАТЬ** *несов.* — 1. *простореч.* к. просадить; 2. *разг.* к. просажать.

**ПРОСА'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд. простореч.* — чәнчеп тишелү.

**ПРОСА'К** *м. обл.* — бау ишү станогы. ◇ **Попасть(ся) впросак** *разг.* — уңайсыз

хәлгә төшү, уңайсыз хәлдә калу, уңайсыз хәлгә очрау.

**ПРОСА'ЛИВАТЬ** I *несов.* — к. просолить.

**ПРОСА'ЛИВАТЬ** II *несов.* — к. просалить.

**ПРОСА'ЛИВАТЬСЯ** I *несов.* — 1. к. просолиться; 2. *страд.* тозлану, нык тозлану.

**ПРОСА'ЛИВАТЬСЯ** II *несов.* — 1. к. просалиться; 2. *страд.* майландырылу, майландырып бетерелү, май сеңдерелү.

**ПРОСА'ЛИТЬ** *сов.* — майландыру, майландырып бетерү; май сеңдерү.

**ПРОСА'ЛИТЬСЯ** *сов.* — майлану, майланып бетү; май сеңү.

**ПРОСА'СЫВАТЬ** *несов.* — к. прососать.

**ПРОСА'СЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. прососаться.

**ПРОСА'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* — к. просочиться.

**ПРОСВА'ТАТЬ** *сов. обл. простореч.* — ярәшү (кызны кияүгә бирергә ризалык бирү).

**ПРОСВА'ТАТЬСЯ** *сов. обл. простореч.* — (берникадәр вакыт) кыз яучылау, кыз яучылап йөрү.

**ПРОСВА'ТЫВАТЬ** *несов. обл. простореч.* — к. просватать.

**ПРОСВЕЖА'ТЬ** *несов. разг.* — к. просвежить.

**ПРОСВЕЖА'ТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. просвежиться; 2. *страд.* һава алыштырылу.

**ПРОСВЕЖИ'ТЬ** *сов. разг.* — һава алыштыру, жилләтү. ◇ **Просвежить голову** — башны ял иттерү, башка ял бирү.

**ПРОСВЕЖИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. (һава) алышыну, чистару; *воздух в комнате просвежился* — бүлмәнең һавасы чистарган; 2. һава алыштыру, һавада йөрү; *после работы надо просвежиться* — эштән соң һавада йөрергә кирәк.

**ПРОСВЕРКА'ТЬ** *сов.* — 1. *разг.* ялт итеп үтеп китү; *просверкнул мимо нас новенький автомобиль* — безнең яныбыздан яңа автомобиль ялт итеп үтеп китте; 2. *(сверкнуть много раз)* ялтырап-ялтырап китү, ялт-йолт итеп китү. ◇ **Всю ночь просверкала молния** — төн буе яшен яшьнәде.

**ПРОСВЕ'РЛИВАТЬ** *несов.* — к. просверлить.

**ПРОСВЕ'РЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — бораулап тишелү.

**ПРОСВЕРЛИ'ТЬ** *сов.* — 1. тишү, бораулап тишү; *просверлить доску буравом* — тактаны борау белән тишү; 2. *перен.* тишкәләп бетерү; *жучок-вредитель просверлил стену* — корткыч-коңгыз стенаны тишкәләп бетергән; 3. тишү; *просверлить дырочку в картоне перочинным ножом* — катырғы кәгазьне пәке белән тишү; 4. (берникадәр вакыт) бораулау, бораулап (берникадәр вакытны) үткәрү; *просверлить десять часов* — ун сәгать вакытны бораулап үткәрү, ун сәгать буе бораулау.

**ПРОСВЕ'Т** *м.* — 1. яктылык, якты сызык, сызылып төшкән яктылык шәүләсе; *в просвете между деревьями* — агачлар арасындагы яктылыкта; 2. якты үтәрлек ярык; *в каземате были только просветы* — казематта якты үтәрлек ярыклар гына бар иде; 3. *архит.* киңлек, иң; *просвет окна равен метру* — тәрәзәнең, иңе бер метр; 4. *воен. (на погонах)* сызык, просвет; 5. *спорт.* ара. ◇ **Наступил просвет** *перен.* — тормыш (хәл) җиңеләя башлады. **Жизнь без просвета** *перен.* — өметсез тормыш.

**ПРОСВЕТИ'ТЕЛЬ** *м. книж.* — 1. *истор.* мәгърифәтче; 2. аң-белем таратучы.

**ПРОСВЕТИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — мәгърифәт...-ы, аң-белем тарату...-ы, агарту...-ы; *просветительная работа* — агарту эшләре. ◇ **Просветительная философия** *истор.* — мәгърифәтчелек философиясе (XVII—XVIII йөзләрдә кайбер буржуаз философик тәгълиматлар исеме).

**ПРОСВЕТИ'ТЕЛЬСКИЙ** *книж.* — мәгърифәтчеләр...-ы, мәгърифәтчелек...-ы; аң-белем тарату...-ы, агарту...-ы; *просветительская деятельность* — мәгърифәтчелек эшчәнлеге.

**ПРОСВЕТИ'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.* — мәгърифәтчелек, аң-белем тарату.

**ПРОСВЕТИ'ТЬ** I *сов. книж.* — укыту, аң-белем тарату, агарту, культура тарату.

**ПРОСВЕТИ'ТЬ** II *сов.* — 1. яктыга куеп карау; *просветить куриное яйцо* — тавык йомыркасын яктыга куеп карау; 2. *спец.* рентгенда карау, рентген нурлары белән яктыртып карау (тикшерү); *просветить лёгкие* — үпкәләрне рентгенда карау.

**ПРОСВЕТИ'ТЬСЯ** I *сов. книж.* — белем алу, культуралашу.

**ПРОСВЕТИ'ТЬСЯ** II *сов.* — рентгенда карау.

**ПРОСВЕТЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — к. просветлеть. ◇ **После продолжительного бреда у больного наступило просветление** — озак вакыт саташып ятканнан соң авыру аңына килде.

**ПРОСВЕТЛЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — рухи тынычлык.

**ПРОСВЕТЛЁННЫЙ** *книж.* — 1. яктыртылган, яктыртыла төшкән; 2. *перен.* якты, аек, өметле; *просветлённый взгляд на жизнь* — тормышка аек карау, тормышка өмет белән карау.

**ПРОСВЕТЛЕ'ТЬ** *сов.* — яктырып китү, ачылып китү; *небо просветлело* — күк йөзе яктырып китте; *лица людей просветлели* — кешеләрнең йөзләре ачылып (яктырып) китте; *сознание просветлело* — аңы ачылып китте.

**ПРОСВЕТЛИ'ТЬ** *сов. книж.* — 1. ачыкландыру, ачыкландыра төшү, яктырту, яктырта төшү; 2. *перен. устар.* рухи тынычлык бирү, рухи яктан тынычландыру.

**ПРОСВЕТЛИ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — 1. ачыклану, ачыклана төшү, яктыру, яктыра төшү; 2. *перен. устар.* рухи яктан тынычлану.

**ПРОСВЕТЛЯ'ТЬ** *несов. книж.* — к. просветлить.

**ПРОСВЕТЛЯ'ТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. к. просветлиться; 2. *страд.* ачыкландырылу, ачыкландырыла төшү, яктыртылу, яктыртыла төшү; 3. *страд. устар.* рухи яктан тынычландырылу.

**ПРОСВЕ'ЧИВАТЬ** *несов.*— 1. к. просветить II; 2. якты(сы) төшү; *солнце просвечивает сквозь тучи* — болытлар аша кояш яктысы төшә; 3. аша (аркылы) күренеп тору, аша (аркылы) күренү, үтәли күренү; *сквозь рубашку просвечивает голое тело* — күлмәге аша шәрә тәне күренеп тора.

**ПРОСВЕ'ЧИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. просветиться II; 2. *страд.* яктыга куеп каралу.

**ПРОСВЕЩА'ТЬ** *несов.*— к. просветить I.

**ПРОСВЕЩА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. просветиться I; 2. *страд.* белем таратылу, культура таратылу.

**ПРОСВЕЩЕ'НЕЦ** *м.*— укытучы, халык мәгарифе өлкәсендә эшләүче, мәгарифче.

**ПРОСВЕЩЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. (*действие*) к. просветить I; 2. укыту, агарту; *просвещение масс* — массаларны агарту; 3. мәгариф; *министр просвещения* — мәгариф министры.

**ПРОСВЕЩЕ'НКА** *ж.*— к. просвещенец.

**ПРОСВЕЩЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— 1. укымышлы булу, укымышлылык, белемлелек, югары культуралылык; 2. *устар.* к. просвещение.

**ПРОСВЕЩЁННЫЙ** — укымышлы, укыган, белемле, югары культуралы; *просвещённый человек* — югары культуралы (укымышлы) кеше.

**ПРОСВИ'РА** *ж. церк.*— просвира (христианнарда дини йолаларны үтәгәндә кулланыла торган ак оннан пешерелгән күмәч).

**ПРОСВИРНЯ'К** *м. бот.*— к. проскурняк.

**ПРОСВИСТА'ТЬ** *сов.*— 1. к. просвистеть; 2. *перен. простореч. фам.* тотып бетерү, туздырып бетерү, җилгә очырып бетерү; *просвистать уйму денег* — бик күп акчаны җилгә очырып бетерү.

**ПРОСВИСТЕ'ТЬ** *сов.*— 1. сызгыру, сызгырып җибәрү, сызгырып кую; *просвистел два раза* — ике кат сызгырды; 2. сызгырып көйләү, сызгырып көй чыгару; *просвистеть марш* — сызгырып марш көйләү; 3. сызгырып үтеп китү, выжлап үтеп китү; *просвистела пуля* — пуля выжлап үтеп китте; 4. (берникадәр вакыт) сайрау, чут-чут итеп сайрап тору, сайрап чыгу; *всю ночь просвистел соловей* — сандугач төн буе сайрады.

**ПРОСВИ'СТЫВАТЬ** *несов.*— к. просвистать, просвистеть.

**ПРОСВИ'СТЫВАТЬСЯ** *несов. страд. простореч. фам.*— тотып бетерелү, җилгә очырып бетерелү (акча турында).

**ПРОСЕ'В** *м. с.-х.*— 1. (*действие*) к. просеять 1; 2. к. огрех 1.

**ПРОСЕВА'ТЬ** *несов. обл.*— к. просеять.

**ПРОСЕВА'ТЬСЯ** *несов. обл.*— 1. к. просеяться; 2. *страд.* иләнү, иләк аша үткәрелү.

**ПРОСЕДА'ТЬ** *несов.*— к. просесть.

**ПРО'СЕДЬ** *ж. мн.* нет — 1. чал; *волосы с проседью* — чал кергән чәч; 2. ак төкләр; *бобёр с проседью* — ак төкләр катнашкан кондыз мехы.

**ПРОСЕ'ИВАТЬ** *несов.*— к. просеять.

**ПРОСЕ'ИВАТЬСЯ** *несов.*— к. просеваться.

**ПРО'СЕК** *м.*, **ПРО'СЕКА** *ж.*— урман межасы, урман ызаны, просека (урманда агачлары киселгән озын тар ачыклык, юл).

**ПРОСЕКА'ТЬ** *несов.*— к. просечь.

**ПРОСЕКА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. просечься; 2. *страд.* агачлар кисеп юл салыну.

**ПРОСЁЛОК** *м.*— авыл юлы, авыл ара юл (авыллар арасындагы таш җәймәгән юл).

**ПРОСЁЛОЧНЫЙ** — авыл ара...; *просёлочная дорога* — авыл ара юл.

**ПРОСЕМИНА'РИЙ** *м.* — просеминарий (югары уку йортларында: семинар тибындагы катлаулырак, чиген занятиеләргә кадәр үткәрелә торган практик занятиеләр).

**ПРОСЕ'СТЬ** *сов.*— 1. бөгелү, сыгылу, сыгылып төшү; *потолок просел* — түшәм сыгылып төшкән; 2. *обл.* (*о растительности*) үсеп чыгу, шытып чыгу.

**ПРОСЕ'ЧЬ** *сов.*— 1. сугып яру; чабып яру (кисү); *просечь кнутом спину лошади* — чыбыркы белән сугып атның аркасын яру; *просечь сапог топором* — итекне балта белән чабып кисү; 2. *обл.* агачларны кисеп юл салу; *просечь дорогу в лесу* — урманда агачларны кисеп юл салу.

**ПРОСЕ'ЧЬСЯ** *сов.*— 1. (*о ткани*) сизрәү, сизрәп тишелү; 2. *устар.* к. прорубиться 1.

**ПРОСЕ'ЯТЬ** *сов.*— 1. иләү, иләктән үткәрү; *просеять муку* — он иләү; 2. (берникадәр вакыт) иләү, иләп (берникадәр вакытны) үткәрү; 3. (берникадәр вакыт) чәчү, чәчеп (берникадәр вакытны) үткәрү.

**ПРОСЕ'ЯТЬСЯ** *сов.*— 1. иләнү; *мука очень хорошо просеялась* — он бик яхшы иләнде; 2. (*просыпаться*) коелу, түгелү, чәчелү.

**ПРОСИГНАЛИЗИ'РОВАТЬ** *сов.*— сигнал бирү.

**ПРОСИГНА'ЛИТЬ** *сов.* — к. просигнализировать.

**ПРОСИДЕ'ТЬ** *сов.*— 1. (берникадәр вакыт) утыру, утырып тору; *просидел целый день* — көн буе утырдым; *просидеть до двух часов* — сәгать икегә кадәр утыру; 2. *разг.* утырып таушалдырып бетерү, утыра-утыра таушалдырып (туздырып) бетерү; *просидеть брюки* — утыра-утыра чалбарны таушалдырып бетерү; 3. утыра-утыра сытып (яньчеп, ватып бетерү); *просидеть кресло* — креслоны утыра-утыра яньчеп бетерү.

**ПРОСИ'ЖИВАТЬ** *несов.*— к. просидеть.

**ПРОСИ'НИВАТЬ** *несов.*— к. просинить.

**ПРОСИ'НИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— синькалану, синькага манылу.

**ПРОСИНИ'ТЬ** *сов.*— 1. синькалау, синькага ману; *просинить халаты* — халатларны синькалау; 2. (берникадәр вакыт) синькалау, синькалап (берникадәр вакытны) үткәрү; *два часа просинила бельё* — ике сәгать вакытны кер синькалап үткәрдем.

**ПРО'СИНЬ** *ж. мн.* нет — 1. *разг.* күгелҗем төс, күгелҗем тап; *узор белый с просинью* — күгелҗем ак бизәк; 2. *обл.* ачык җир (күктә), болыт арасы.

**ПРОСИ'ТЕЛЬ** *м.*, **ПРОСИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж. офиц. устар.*— сораучы, үтенүче.

**ПРОСИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.*— сорау...-ы,

үтенү...-ы; үтенүле, ялынулы; *просительный тон* — үтенү тоны, үтенүле тон; *просительный взгляд* — ялынулы (үтенүле) караш.

**ПРОСИ'ТЕЛЬСКИЙ** — сораучы...-ы; *просительский вид* — сораучы кыяфәте.

**ПРОСИ'ТЬ** *несов.* — 1. (*обращаться с просьбой*) сорау, үтенү; 2. (*приглашать*) чакыру; 3. *обл. устар.* (*нищенствовать*) сорану, теләнү, сораныл йөрү, теләнеп йөрү, хәер сорашу; 4. *устар.* (*подавать в суд жалобу*) судка бирү. ◇ **Милости просим** — к. милость. **Прошу (вас)** *разг.* — рәхим итегез. **Прошу покорнейше** *разг. устар.* — 1. рәхим итегез; 2. *вводн. сл.* искиткеч хәл, исең китәр.

**ПРОСИ'ТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. сорау, рөхсәт сорау; *проситься в избу* — өйгә керергә рөхсәт сорау; 2. алуны сорау; *проситься на службу* — хезмәткә алуны сорау. ◇ **Слово просится с языка** — телем кычытып тора, әйтәсем килеп тора.

**ПРОСИЯ'ТЬ** *сов.* — 1. балку, балкып китү, ялтырый башлау, җем-җем итә башлау; *солнце просияло* — кояш балкыды; 2. *перен.* (*стать приветливым*) йөзе ачылып китү, йөзе яктырып китү.

**ПРОСКА'БЛИВАТЬ** *несов.* — к. проскоблить.

**ПРОСКА'БЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — кырып тишелү, кырып тишеп чыгарылу, кыра-кыра тишеп чыгарылу.

**ПРОСКАКА'ТЬ** *сов.* — 1. (тиз вакыт эчендә) йөреп чыгу; *раз пять или шесть всю Россию вдоль и поперёк проскакал* (Тургенев) — бөтен Россияне биш-алты тапкыр аркылыга-буйга йөреп чыктым; 2. чаптырып үтеп китү; *проскакал верховой* — жайдак чаптырып үтеп китте; 3. *разг.* сикергәләп бару, сикергәләп барып житү; *мальчик проскакал до забора* — малай сикергәләп коймага кадәр барып житте; 4. (берникадәр вакыт) сикереп йөрү; сикереп йөреп (берникадәр вакытны) үткәрү; *весь день дети проскакали* — балалар көн буе сикереп йөрделәр.

**ПРОСКА'КИВАТЬ** *несов.* — к. проскочить, проскакать.

**ПРОСКА'ЛЬЗЫВАТЬ** *несов.* — к. проскользнуть.

**ПРОСКВОЗИ'ТЬ** *сов. разг.* — жил бәрү, жил тию, жил бәреп салкын тию; *его просквозило* — аңа жил бәргән.

**ПРОСКЛОНЯ'ТЬ** *сов.* — төрләндерү (исемнәрне килешләр белән төрләндерү).

**ПРОСКОБЛИ'ТЬ** *сов.* — 1. кырып тишү, кырып тишеп чыгару, кыра-кыра тишеп чыгару; *проскоблить бумагу ножом* — кәгазьне пычак белән кырып тишеп чыгару; 2. (берникадәр вакыт) кыру, кырып (берникадәр вакытны) үткәрү.

**ПРОСКОЛЬЗНУ'ТЬ** *сов.* — 1. сиздермичә үтеп китү, шыпырт кына үтеп китү, яшерен генә үтеп китү; *он проскользнул в сад* — ул сиздермичә генә бакчага үтеп китте; 2. сизелү, сизелеп китү; *в его словах проскользнула ирония* — аның сүзләрендә ирония сизелеп китте.

**ПРОСКОЧИ'ТЬ** *сов.* — 1. тиз генә үтеп китү, йөгереп үтеп китү; *проскочил мимо него* — аның янынван тиз генә үтеп китте; 2. үтү, чыгу, чыгып китү, үтеп китү; *собака проскочила в отверстие, которое было в заборе* — эт коймадагы тишектән (койма тишегеннән) чыгып китте; 3. *разг.* төшеп китү; *проскочило между пальцев* — бармаклар арасыннан төшеп китте; 4. *разг. фам.* калу, китү; *в корректуре проскочило несколько ошибок* — корректурада берничә хата киткән; 5. *перен. разг. неодобр.* төрле алдаулы юллар белән дәрәҗәгә күтәрелү; *проскочить в секретари* — төрле алдаулы юллар белән секретарь дәрәҗәсенә күтәрелү.

**ПРОСКРЕЖЕТА'ТЬ** *сов.* — 1. тешләрне шыкырдату, тешләрне шыкырдатып алу; 2. тешләрне шыкырдатып әйтү, әйтеп кую.

**ПРОСКРЕСТИ'** *сов. разг.* — 1. кыра-кыра тишеп чыгару; 2. кимерә-кимерә тишеп чыгару; тырный-тырный тишеп чыгару; *мыши проскребли пол* — тычканнар кимерә-кимерә идәнне тишеп чыгарганнар; 3. к. проскрестись 3.

**ПРОСКРЕСТИ'СЬ** *сов. разг.* — 1. тырмашып керү; 2. (берникадәр вакыт) тырмашу, тырмашып (берникадәр вакытны) үткәрү; 3. кыру, кырып үткәрү; кимерү, кимереп үткәрү.

**ПРОСКРИПЕ'ТЬ** *сов.* — 1. шыгырдау, шыгырдап китү; *проскрипела полозица* — сайгак шыгырдап китте; 2. *разг.* шыгырдап үтеп китү; *по улице проскрипел обоз* — урам буйлап олау шыгырдап үтеп китте; 3. *разг. фам.* шыгырдау (яшәү мәгънәсендә); *много лет проскрипит ещё* — күп еллар шыгырдар әле (яшәр әле).

**ПРОСКРИПЦИО'ННЫЙ** *истор.* — проскрипцион; *проскрипционный список* — проскрипцион исемлек (борынгы Римда — политик җинаятьләре өчен законнан тыш дип игълан ителгән кешеләрнең исемлеге; буржуаз илләрдә — кара исемлек).

**ПРОСКРИ'ПЦИЯ** *ж. истор.* — проскрипция (борынгы Римда — политик җинаять өчен халык алдында гаепләп, гаепләнүчеләрне законнан тыш дип игълан итү).

**ПРОСКУРНЯ'К** *м. бот.* — мәче борчагы.

**ПРОСКУЧА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. (берникадәр вакыт) эч пошу; *весь вечер проскучал* — кич буе эчем пошты; 2. сагыну, сагынып үткәрү.

**ПРОСЛА'БИТЬ** *сов. безл.* — эч китү.

**ПРОСЛА'ВИТЬ** *сов.* — 1. (*сделать известным*) данын тарату, танылу, данлы итү; 2. *книж.* (*воздать хвалу*) мактау; 3. *разг.* (*ославить*) даның чыгару, яман атын сату.

**ПРОСЛА'ВИТЬСЯ** *сов.* — дан казану, шөһрәт алу, даны таралу.

**ПРОСЛАВЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. прославить.

**ПРОСЛАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. прославиться; 2. *страд.* даны таратылу, танытылу; макталу.

**ПРОСЛА'ИВАТЬ** *несов.* — к. прослоить.

**ПРОСЛА'ИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. прослоиться; 2. *страд.* катлы-катлы итеп өеп куелу, аралаштырып өеп куелу.

**ПРОСЛЕДИ'ТЬ** *сов. книж.* — 1. артыннан күзәтеп бару, эзеннән барып табу;

2. күзәтү, күзәтеп бару; *проследить явление до конца* — күренешне ахырына кадәр күзәтү.

**ПРОСЛЕ'ДОВАТЬ** *сов. книж. офиц. тоже.*— китү, үтеп китү, узып китү, китеп бару.

**ПРОСЛЕ'ЖИВАТЬ** *несов. книж.* — к. проследить.

**ПРОСЛЕ'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд. книж.*— күзәтелү.

**ПРОСЛЕЗИ'ТЬСЯ** *сов.* — күзләргә яшь тулу, күзләргә яшь килү, күзләр яшьләнү.

**ПРОСЛОИ'ТЬ** *сов.* — катлы-катлы итеп өю, катлы-катлы итеп өеп кую, аралаштырып өеп кую, катлы-катлы итеп ясау.

**ПРОСЛОИ'ТЬСЯ** *сов.*— катлам-катлам булып урнашу.

**ПРОСЛО'ЙКА** *ж.*— 1. *только ед. (действие)* к. прослоить; 2. катлам, катлау.

**ПРОСЛОНЯ'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.*— (берникадәр вакыт) эшсез йөрү, эшсез йөреп (берникадәр вакытны) үткәрү.

**ПРОСЛУ'ЖИВАТЬ** *несов.*— к. прослужить.

**ПРОСЛУЖИ'ТЬ** *сов.*— (берникадәр вакыт) хезмәт итү; *прослужил в управлении три года* — өч ел идарәдә хезмәт итте. ◇ **Сапоги прослужили мне два сезона** — мин итекләрне ике сезон кидем. **Пальто прослужит ещё сезон** — пальто тагын бер сезонга чыдар.

**ПРОСЛУ'ШАТЬ** *сов.*— 1. тыңлау, ахырына кадәр тыңлау, тыңлап бетерү; *прослушать оперу* — опера тыңлау, операны ахырына кадәр тыңлау; 2. *разг.* ишетми калу; *простите, я прослушал, что Вы сказали; повторите, пожалуйста* — гафу итегез, мин Сез әйткәнне ишетми калдым; кабатлагыз, зинһар; 3. (берникадәр вакыт) тыңлау, тыңлап тору, тыңлап (берникадәр вакытны) үткәрү; *два часа прослушал лекцию* — ике сәгать (буена) лекция тыңладым, ике сәгать вакытны лекция тыңлап үткәрдем. ◇ **Прослушать лёгкие, прослушать сердце** *мед.*— үпкәләрне тыңлап карау, йөрәкне тыңлап карау (махсус трубка ярдәмендә берәр авыру юкмы икәнлеген белү өчен).

**ПРОСЛУ'ШИВАТЬ** *несов.* — к. прослушать.

**ПРОСЛУ'ШИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— тыңлану, беткәнче тыңлану.

**ПРОСЛЫВА'ТЬ** *несов.*— к. прослыть.

**ПРОСЛЫ'ТЬ** *сов.*— 1. *с отриц. оттенком* танылу, аты чыгу, даны чыгу; 2. *с полож. оттенком* дан (шөһрәт) казану.

**ПРОСЛЫ'ШАТЬ** *сов. разг.*— ишетү, ишетеп белү.

**ПРОСМА'ЛИВАТЬ** *несов.*— к. просмолить.

**ПРОСМА'ЛИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. просмолиться; 2. *страд.* сумала сеңдерелү, сумалалап чыгылу.

**ПРОСМА'ТРИВАТЬ** *несов.*— к. просмотреть.

**ПРОСМА'ТРИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. карап чыгылу, күздән үткәрелү; 2. күрми калдырылу, (хата) җибәрелү.

**ПРОСМЕ'ИВАТЬ** *несов. простореч.*— к. просмеять.

**ПРОСМЕЯ'ТЬ** *сов. простореч.*— көлкегә калдыру, мыскыллап көлү, мәсхәрәләү, мәсхәрә итү, мыскыллау, мыскыл итү.

**ПРОСМОЛИ'ТЬ** *сов.*— сумалалау, сумалалап чыгу, сумала сеңдерү.

**ПРОСМОЛИ'ТЬСЯ** *сов.*— сумалалану.

**ПОСМО'ТР** *м.*— 1. *(действие)* к. просмотреть; 2. *разг.* (күрми) калган хата, сизелмәгән хата; *нечаянный просмотр* — сизелми калган хата.

**ПРОСМОТРЕ'ТЬ** *сов.*— 1. карап чыгу, караштырып чыгу, күздән үткәрү, күз йөгертеп чыгу, күз йөртеп чыгу; *просмотреть книгу* — китапны карап чыгу; 2. күрми калдыру, хата җибәрү; *просмотреть ошибку* — хатаны күрми калдыру, хата җибәрү; 3. (берникадәр вакыт) карау, карап тору, карап (берникадәр вакытны) үткәрү; *всю ночь просмотрел на звезды* — төн буе йолдызларга карап тордым.

**ПРОСМО'ТРЩИК** *м.*— тикшереп торучы.

**ПРОСНУ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. уяну, уянып китү, йокыдан уяну; *она уже проснулась* — ул йокысыннан уянды инде; 2. *перен. книж.* уяну; *проснулось злое чувство* — ачу хисе уянды; 3. *перен. книж.* туу, барлыкка килү; *проснулся день* — көн туды.

**ПРО'СО** *ср.*— 1. *только ед.* тары; 2. *обл. мн.* тарылар, тары кырлары.

**ПРОСОБИРА'ТЬ** *сов. разг.*— (берникадәр вакыт) җыю, җыеп (берникадәр вакытны) үткәрү; *целый день прособирали грибы* — көн буе гөмбә җыйдык.

**ПРОСОБИРА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— (берникадәр вакыт) җыену, җыенып (берникадәр вакытны) үткәрү; *прособирались весь месяц на юг* — бер ай буе көньякка китәргә җыендык.

**ПРОСО'ВЫВАТЬ** *несов.*— к. просунуть.

**ПРОСО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.*— к. просунуться.

**ПРОСО'ДИЯ** *ж. мн.* нет, *филол.*— просодия (1. телдәге басымлы һәм басымсыз, озын һәм кыска иҗекләрнең әйтелү системасы; 2. *лит.* шигырьдәге иҗекләрнең үзара мөнәсәбәте турындагы тәгълимат).

**ПРОСО'Л** *м. мн.* нет, *спец.*— тозлану дәрәҗәсе, тозлану сыйфаты.

**ПРОСОЛИ'ТЬ** *сов.*— 1. тозлау, тоз сеңдерү; *просолить мясо* — ит тозлау; 2. (берникадәр вакыт) тозлау, тозлап (берникадәр вакытны) үткәрү; *целый день просолила рыбу* — көн буе балык тозладым.

**ПРОСОЛИ'ТЬСЯ** *сов.*— тозлану.

**ПРОСОРУ'ШКА** *ж. с.-х.*— тары яргыч.

**ПРОСО'С** *м. обл. простореч.*— су юып тишкән урын.

**ПРОСОСА'ТЬ** *сов.*— 1. (юып) тишү, тишеп чыгу; *вода плотину прососала* — су буаны юып тишкән; 2. имә-имә тишеп чыгару, имә-имә ерту; *ребёнок насквозь прососал соску* — бала имә-имә имезлекне тишеп чыгарган; 3. (берникадәр вакыт) иму, имеп тору, имеп чыгу; *ребёнок весь вечер прососал соску*—бала кич буе имезлек имде.

**ПРОСОСА'ТЬСЯ** *сов.*— сарку, саркып үтү.

**ПРОСО'ХНУТЬ** *сов.*— кибү, кибеп житү.

**ПРОСОЧИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. сарку, үтү, саркып үтү; *в лодку просочилась вода* — көймәгә су үткән; 2. *перен. разг. фам.* таралу; *просочились слухи* — хәбәрләр таралды.

**ПРОСПА'ТЬ** *сов.*— 1. (берникадәр вакыт) йоклау, йоклап (берникадәр вакытны) үткәрү; *проспал пять часов подряд* — биш сәгать рәттән йокладым; 2. *разг.* йоклап калу; *проспал лекцию* — лекциядән йоклап калганмын.

**ПРОСПА'ТЬСЯ** *сов.*— 1. (*о пьяных*) йоклап айну; 2. (*выспаться*) туйганчы йоклау, йоклап тую.

**ПРОСПЕ'КТ** I *м.*— проспект (киң зур урам).

**ПРОСПЕ'КТ** II *м.*— проспект (1. *книж.* берәр нәрсәнең планы, эчтәлеге; 2. *торг.* сәүдә прейскуранты).

**ПРОСПИРТОВА'ТЬ** *сов. спец.*— спиртлау, спирт сеңдерү.

**ПРОСПИРТОВА'ТЬСЯ** *сов. спец.*— спиртлану, спирт сеңү.

**ПРОСПИРТО'ВЫВАТЬ** *несов.*— к. проспиртовать.

**ПРОСПИРТО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. спец.*— 1. к. проспиртоваться; 2. *страд.* спиртлану, спирт сеңдерелү.

**ПРОСПО'РИВАТЬ** *несов.*— к. проспорить.

**ПРОСПО'РИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— оттырылу.

**ПРОСПО'РИТЬ** *сов.*— 1. *разг.* (бәхәсләшеп) оттыру; *проспорил десять рублей* — (бәхәсләшеп) ун сум акча оттырдым; 2. (берникадәр вакыт) бәхәсләшү, сүз көрәштерү, бәхәсләшеп (берникадәр вакытны) үткәрү, сүз көрәштереп (берникадәр вакытны) үткәрү; *проспорили целый час* — бер сәгать вакытны бәхәсләшеп үткәрдек.

**ПРОСПРЯГА'ТЬ** *сов. грам.*— төрләндерү (фигыльне зат, заман, сан белән төрләндерү).

**ПРОСРО'ЧИВАТЬ** *несов.*— к. просрочить.

**ПРОСРО'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— кичектерелү, срогы уздырылу. ◇ **Документ просрочен** — документның срогы чыккан.

**ПРОСРО'ЧИТЬ** *сов.*— кичектерү, срогын уздыру, срогыннан (вакытыннан) соңга калдыру, срогында үтәмәү.

**ПРОСРО'ЧКА** *ж.*— кичектерү, срогын уздыру, срогы чыгу.

**ПРОСТА'ВИТЬ** *сов.*— 1. *офиц.* язу, (язып) кую, күрсәтү; *проставить дату в удостоверении* — таныклыкта датасын күрсәтү, таныклыкка датасын язып кую; 2. *простореч. фам.* оттыру (бәхәсләшеп яки уенда); *проставил двадцать рублей* — егерме сум акча оттырдым.

**ПРОСТА'ВИТЬСЯ** *сов. простореч. фам.*— отылу, оттыру (бәхәсләшеп яки уенда).

**ПРОСТАВЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. проставить.

**ПРОСТАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. *простореч. фам.* к. проставиться; 2. *страд.* язылу, (язып) куелу, күрсәтелү.

**ПРОСТА'ИВАТЬ** *несов.*— к. простоять.

**ПРОСТА'К** *м.*— 1. беркатлы кеше; 2. *театр.* беркатлы кеше ролен башкаручы артист амплуасы; 3. *разг. фам.* гади кеше.

**ПРОСТА'ЧКА** *ж. разг.*— к. простак 1.

**ПРОСТАЧО'К** *м. разг. фам.*— к. простак I.

**ПРОСТЕГА'ТЬ** *сов. спец.*— сыру, сырып чыгу; *простегать одеяло* — юрган сырып чыгу.

**ПРОСТЁГИВАТЬ** *несов. спец.*— к. простегать.

**ПРОСТЁГИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— сырылу, сырып чыгылу.

**ПРОСТЕЛИ'ТЬ** *сов. простореч.*— к. прослать.

**ПРОСТЕ'НОК** *м.*— 1. ике арадагы стена (тәрәзәләр яки ишекләр арасындагы стена); 2. *обл.* (*перегородка*) бүлем.

**ПРОСТЕРЕ'ТЬ** *сов. книж.*— к. простирать I.

**ПРОСТЕРЕ'ТЬСЯ** *сов. книж.*— к. простираться 1, 2.

**ПРОСТЕРЕ'ЧЬ** *сов.*— 1. (берникадәр вакыт) саклау, саклап (берникадәр вакыт) үткәрү; саклап тору, саклап чыгу, каравыллап тору, каравыллап чыгу; *мальчики всю ночь простерегли лошадей* — малайлар төн буе атлар саклап чыктылар; 2. *обл. неодобр.* авыз ачып калу, коры калу, колак кагу, югалту; *уснул пастух и простерёг половину стада* — көтүче йоклап киткән дә ярты көтүеннән коры калган (ярты көтүен югалткан).

**ПРОСТЕ'ТЬ** *несов. разг.*— 1. (*становиться проще*) гадиләшү, гадиләшә бару; 2. (*становиться простаком*) беркатлылану, беркатлылана бару.

**ПРОСТИЛА'ТЬ** *несов.*— к. прослать.

**ПРОСТИЛА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — җәеп чыгылу.

**ПРОСТИРА'ТЬ** I *несов. книж.*— 1. *устар.* сузу; җәеп сузу; *простирать руки вперёд* — кулларны алга сузу; 2. *перен. книж.* (*устремлять*) юнәлдерү, җәю, сузу.

**ПРОСТИРА'ТЬ** II *сов. разг.*— 1. (кер) юу, (кер) уу, юып алу, уып алу; *простирай рубашку получше* — күлмәкне яхшырак ю; 2. (берникадәр вакыт) кер юу, кер уу, кер юып (берникадәр вакытны) үткәрү, кер уып үткәрү; *простирала бельё до ночи* — төнгә кадәр кер юдым.

**ПРОСТИРА'ТЬСЯ** *несов. книж.*— 1. сузылу, җәелү; *леса на севере простираются на тысячи километров* — төньякта урманнар меңнәрчә километрларга җәелә; 2. *устар.* сузылу; *рука простирается к нему* — кул аңар сузыла; 3. *страд.* сузылу; юнәлдерелү, җәелү.

**ПРОСТИ'РЫВАТЬ** *несов. разг.*— к. простирать II.

**ПРОСТИ'РЫВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— юылу, уылу (кер турында).

**ПРОСТИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.*— гафу итәрлек, кичерерлек; гафу ителерлек, кичерелерлек.

**ПРОСТИТУИ'РОВАТЬ** *несов.* и *сов. книж.*— 1. *редко* бозык юлга кертү (бастыру), фәхишәлек белән шөгыльләнергә мәҗбүр итү; 2. *перен. презрит.* сатлык юлга бастыру (кертү); 3. *только несов. презрит.* сатылу, фикере белән сату итү.

**ПРОСТИТУИ'РОВАТЬСЯ** *книж.*— 1. *сов.* и *несов. редко* бозык юлга басу, фахишәгә әйләнү, фахишәлек белән шөгыльләнә башлау; 2. *несов. страд.* бозык юлга бастырылу (кертелү); бозылу.

**ПРОСТИТУ'ТКА** *ж.*— 1. фахишә, уйнашчы, бозык хатын; 2. *перен. презрит.* сатлык җан, мораль яктан черēп таркалган кеше.

**ПРОСТИТУ'ЦИЯ** *ж.*— фәхеш, фахишәлек, бозыклык.

**ПРОСТИ'ТЬ** *сов.*— гафу итү, кичерү. ◇ **Простите** — 1. гафу итегез, кичерегез; 2. *устар.* хушыгыз, сау булыгыз, исән булыгыз. **Последнее прости (сказать)** *устар.*— бәхилләшү, соңгы мәртәбә саубуллашу, мәңгегә саубуллашу. **Прости-прощай** *нар.-поэт.*— хуш, исән бул.

**ПРОСТИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. саубуллашу, хушлашу; *друзья простились* — дуслар саубуллаштылар; 2. *разг.* кичерелү, гафу ителү; *это тебе не простится* — бу сина гафу ителмәс; 3. *устар.* (*попросить прощения*) гафу үтенү.

**ПРОСТЛА'ТЬ** *сов.*— 1. (*постлать вдоль*) (буйга) җәеп чыгу; 2. (берникадәр вакыт) җәю, җәеп (берникадәр вакытны) үткәрү; *простлали лён целый день* — көн буе җитен җәйдек.

**ПРО'СТО** *нареч.*— 1. җиңел, җиңел, авсат, бик гади; *это очень просто сделать* — моны эшләргә бик җиңел, моны эшләве бик җиңел; 2. болай гына, юри генә; *просто сказал и всё* — тик болай гына әйттем; 3. чынчыннан, чын мәгънәсендә, фәкать; *это просто издевательство!*— бу чын мәгънәсендә мыскыл итү! 4. тик, гына; *мне просто хочется домой* — минем өйгә кайтасым гына килә; 5. *разг.* ялгыш кына, болай гына; *просто сорвалось с языка* — ялгыш кына телемнән ычкынды. ◇ **Просто-напросто** — к. напросто. **Просто так** *разг.*— тик болай гына.

**ПРОСТОВА'ТОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.*— беркатлылык, беркатлы булу, юләрсымак булу.

**ПРОСТОВА'ТЫЙ** *разг.*— беркатлырак, юләрсымак, иләс-миләс.

**ПРОСТОВОЛО'СЫЙ** *разг.*— ялан баш..., ялан башлы.

**ПРОСТОДУ'ШИЕ** *ср. мн.* нет — эчкерсезлек, саф күңеллелек, самимилек, эчкерсез булу, саф күңелле булу; *простодушие характера* — характерның эчкерсезлеге.

**ПРОСТОДУ'ШНИЧАТЬ** *несов. разг. неодобр.*— эчкерсез булып күренергә тырышу.

**ПРОСТОДУ'ШНЫЙ** — эчкерсез, саф күңелле, самими.

**ПРОСТО'Й** I — 1. гади, җиңел; *простое дело* — җиңел эш; *простое платье* — гади күлмәк; 2. тупас; *простая кожа* — тупас күн; 3. простой, түбәнчелекле; *простой человек* — простой кеше; 4. *разг.* беркатлы; *быть до такой степени простым* — шул кадәр беркатлы булырга; 5. *устар. обл.* буш; *простая посуда* — буш савыт.

**ПРОСТО'Й** II — простой, туктап тору, (вакытлыча) эшләмичә тору.

**ПРОСТО'ЙНЫЙ** *спец.*— простой...-ы, туктап тору...-ы, *простойное время* — простой вакыты; *простойные часы* — туктап тору сәгатьләре.

**ПРОСТОКВА'ША** *ж. мн.* нет — әчегән сөт.

**ПРОСТОЛЮДИ'Н** *м.*, **ПРОСТОЛЮДИ'НКА** *ж. дореввол.*— гади катлау кешесе, гади халыктан чыккан кеше (ягъни аксөякләрдән түгел, ә эшче, крестьян, мещаннар катлавыннан).

**ПРОСТОНАРО'ДНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж. дореввол.*— гади халыкка хас булу.

**ПРОСТОНАРО'ДНЫЙ** *дореввол.*— гади халыкка хас булган, гади халык...-ы; *простонародная одежда* — гади халык киеме.

**ПРОСТОНАРО'ДЬЕ** *ср. мн.* нет, *дореввол.*— гади халык (буржуаз-дворян җәмгыятьтә эксплуатацияләнгән сыйныф кешеләренә карата кимсетеп әйтелгән сүз).

**ПРОСТОНА'ТЬ** *сов.*— 1. ыңгырашып кую; *больной простонал* — авыру ыңгырашып куйды; 2. (*произнести со стоном*) ыңгырашып әйтеп кую, ыңгырашкан тавыш белән әйтеп кую; 3. (берникадәр вакыт) ыңгырашу, ыңгырашып чыгу, ыңгырашып (берникадәр вакытны) үткәрү; *простонал всю ночь* — төн буе ыңгырашып чыкты.

**ПРОСТО'Р** *м. книж.*— киңлек, иркенлек.

**ПРОСТОРЕ'ЧИЕ** *ср. мн.* нет, *лингв.*— 1. гади сөйләм (әдәби телдә шаяру, кимсетү, көлү һ. б. чагылдыруда стилистик чара булып хезмәт итә торган, сөйләшү теленнән алынган сүзләр яки грамматик формалар); 2. *устар.* сөйләшү теле (ягъни китап теле түгел, әдәби тел түгел).

**ПРОСТОРЕ'ЧНЫЙ** *лингв.*— 1. гади сөйләмгә хас (булган); 2. *устар.* сөйләшү теленә хас (булган).

**ПРОСТО'РНЫЙ** — киң, иркен.

**ПРОСТОРОЖИ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. (берникадәр вакыт) саклау, саклап тору, саклап (берникадәр вакытны) үткәрү; 2. *ирон.* (берәр нәрсәне саклаганда) авыз ачып калу, колак кагу, югалту.

**ПРОСТОСЕРДЕ'ЧИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— саф күңеллелек, саф күңелле булу, эчкерсез булу, мәкерсезлек.

**ПРОСТОСЕРДЕ'ЧНЫЙ** *книж.*— саф күңелле, хәйләсез, эчкерсез, мәкерсез.

**ПРОСТОТА'** *ж. мн.* нет — 1. гадилек; җиңеллек; 2. эчкерсезлек, гадилек, простойлык; *простота человека* — кешенең гадилеге; 3. беркатлылык; юләрлек, ахмаклык; *простота — хуже воровства* (*посл.*)— ахмаклык караклыктан да начар. ◇ **Святая простота** *разг.*— беркатлылык, беркатлы кеше. **По простоте сердечной** *разг.*— беркатлылыгы аркасында.

**ПРОСТОФИ'ЛЯ** *м.* и *ж. разг.*— ахмак, ачык авыз, пешмәгән, җебегән.

**ПРОСТОЯ'ТЬ** *сов.*— 1. басып тору; *с минуту простояли молча* — бер минутка якын сөйләшмичә басып тордылар; 2. туктап тору, буш тору, тик тору; эшләми то-

ру; *машина простояла месяц* — машина бер ай туктап торды; 3. (берникадәр вакыт) тору, яраклы булу, чыдау; *дом простоит ещё пять лет без ремонта* — йорт ремонтсыз тагы биш ел торыр әле, йорт тагы бер биш елга ярәр әле; 4. *простореч.* таптап пычратып бетерү; *в зале простояли весь пол* — залның идәнен таптап пычратып бетергәннәр.

**ПРОСТРА'ГИВАТЬ** *несов.* — к. прострогать.

**ПРОСТРА'ГИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. ышкылап ясалу; 2. ышкылап шомартылу.

**ПРОСТРА'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. киңлек, зурлык; 2. озынлык, тулылык.

**ПРОСТРА'ННЫЙ** *книж.* — 1. киң, бик зур; *пространные земельные владения* — бик зур жир биләмәләре; 2. озын, тулы; *пространное письмо* — озын хат.

**ПРОСТРА'НСТВЕННЫЙ** — пространство...-ы; *пространственные и временные отношения* — пространство һәм вакыт мөнәсәбәтләре.

**ПРОСТРА'НСТВО** *ср.* — 1. пространство; *пространство и время* — пространство һәм вакыт; 2. аралык, урын; *свободное пространство между дверью и окном* — ишек белән тәрәзә арасындагы буш урын; 3. *книж.* мәйдан, пространство; *на севере огромные пространства покрыты лесом* — төньякта бик зур мәйданнар урман белән капланган.

**ПРОСТРА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *книж.* — прострация, рухи төшенкелек, дөньядан бизү.

**ПРОСТРА'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. прострочить.

**ПРОСТРА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — каеп чыгылу, тегеп чыгылу.

**ПРОСТРЕ'Л** *м. разг.* — чәнчешү (суык тиюдән).

**ПРОСТРЕ'ЛИВАТЬ** *несов.* — 1. к. прострелить; 2. *воен.* утка тоту; *простреливать позиции противника с флангов* — дошманның позицияләрен фланглардан утка тоту.

**ПРОСТРЕЛИ'ТЬ** *сов.* — атып тишү.

**ПРОСТРЕЛЯ'ТЬ** *сов.* — 1. *разг.* атып карау, атып (сынап) карау (мәсәлән, яңа мылтыкны); 2. (берникадәр вакыт) ату, атып тору, атып (берникадәр вакытны) үткәрү; *прострелять целый вечер* — кич буе ату.

**ПРОСТРИГА'ТЬ** *несов.* — к. прострично.

**ПРОСТРИГА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — кыркып чыгылу, кыркып алыну.

**ПРОСТРИ'ЧЬ** *сов.* — 1. *(выстричь)* кыркып чыгу, кыркып алу, китәрү, чәч алу; 2. (берникадәр вакыт) кырку, китәрү, чәч алу, кыркып (берникадәр вакытны) үткәрү.

**ПРОСТРОГА'ТЬ** *сов.* — 1. ышкылап уеп ясау, ышкылап уеп алу; *прострогать желобок* — кечкенә генә улак уеп ясау; 2. ышкылап шомарту; *прострогать доску* — тактаны ышкылап шомарту; 3. (берникадәр вакыт) ышкылау, ышкылап (берникадәр вакытны) үткәрү.

**ПРОСТРОЧИ'ТЬ** *сов. спец.* — 1. тегеп чыгу, каеп чыгу; *прострочить платье* — күлмәкне каеп чыгу; 2. (берникадәр вакыт) тегү, каю, тегеп (берникадәр вакытны) үткәрү, каеп үткәрү.

**ПРОСТРУГА'ТЬ** *сов. обл.* — к. прострогать.

**ПРОСТРУ'ГИВАТЬ** *несов. обл.* — к. прострогать.

**ПРОСТРУ'ГИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — к. прострагиваться.

**ПРОСТУ'ДА** *ж. мн.* нет — салкын тию, суык тию.

**ПРОСТУДИ'ТЬ** *сов.* — 1. салкын тидерү, суык тидерү; *простудить ребёнка* — балага салкын тидерү; 2. *простореч.* суыту; *простуди чай, а потом пей* — чәйне (башта) суыт, аннан соң эч (ягъни чәйне суытып эч).

**ПРОСТУДИ'ТЬСЯ** *сов.* — салкын тидерү, суык тидерү, суык алдыру.

**ПРОСТУ'ДЛИВЫЙ** *простореч.* — салкынга бирешүчән, тиз салкын тиючән.

**ПРОСТУ'ДНЫЙ** — салкын тиюдән булган, суык тиюдән булган; *простудное заболевание* — салкын тиюдән булган (була торган) авыру.

**ПРОСТУЖА'ТЬ** *несов.* — к. простудить.

**ПРОСТУЖА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. простудиться; 2. *страд.* салкын тидерелү, суык тидерелү.

**ПРОСТУ'ЖИВАТЬ** *несов. разг.* — к. простужать.

**ПРОСТУ'ЖИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. простужаться.

**ПРОСТУ'КАТЬ** *сов. разг.* — 1. *(пробить ударами)* суккалап тишеп чыгару; 2. *мед.* к. выстукать 1; 3. (берникадәр вакыт) шакылдату, шакылдатып тору, шакылдатып (берникадәр вакытны) үткәрү.

**ПРОСТУ'КИВАТЬ** *несов.* — к. простукать.

**ПРОСТУПА'ТЬ** *несов.* — к. проступить.

**ПРОСТУПИ'ТЬ** *сов.* — 1. саркып чыгу; бөркеп чыгу; бөрчек-бөрчек булып чыгу; *пот проступил на спине* — аркасына бөрчек-бөрчек булып тир чыккан; 2. аз гына күренү, урыны-урыны белән генә күренү, андамонда гына күренү.

**ПРОСТУ'ПОК** *м. книж.* — гаеп эш, ярамаган эш.

**ПРОСТУ'ХА** *ж. простореч.* — к. простачка.

**ПРОСТУЧА'ТЬ** *сов.* — 1. шакылдатып алу, шакылдатып кую; *вдали простучал сторож* — ерakta каравылчы шакылдатып куйды; 2. (берникадәр вакыт) шакылдату, шакылдатып тору, шакылдатып (берникадәр вакытны) үткәрү; 3. *разг.* дыңгырдап үтеп китү; *мимо дома простучал обоз* — өй янынннан олау дыңгырдап үтеп китте.

**ПРОСТУ'ШКА** *ж. разг. фам.* — к. простачка.

**ПРОСТЫВА'ТЬ** *несов.* — к. простыть.

**ПРОСТЫ'ЛЫЙ** *обл.* — суынган.

**ПРОСТЫ'НКА** *ж. разг.* — к. простыня.

**ПРОСТЫ'ННЫЙ** — простыня...-ы, җәймә...-ы, простынялык..., җәймәлек...; *простынное полотно* — простынялык полотно.

**ПРОСТЫ'НУТЬ** *сов. простореч.* — к. простыть.

**ПРОСТЫ'НЯ** *м.* и *ж. обл.*— к. простак.
**ПРОСТЫНЯ'** *ж.*— простыня, җәймә.
**ПРОСТЫ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. суыну; *чай давно простыл* — чәй күптән суынды; 2. *просторечь.* салкын тию, суык тию; *сторож простыл* — каравылчыга суык тигән; 3. *перен.* (*успокоиться*) тынычлану, суыну. ◇ След простыл *разг.*— эзе дә калмаган, эзе сенгән, җилләр искән, эзе суынган.
**ПРОСТЯ'К** *м.*, **ПРОСТЯ'ЧКА** *ж. просторечь.*— к. простак 1.
**ПРОСУДИ'ТЬ** *сов. просторечь.*— 1. *устар.* (акчасын, милкен) судка тыгу, судка тыгып бетерү; *просудил всё своё имущество* — бөтен милкен судка тыгып бетергән; 2. (берникадәр вакыт) хөкем итү, хөкем итеп утыру.
**ПРОСУДИ'ТЬСЯ** *сов. просторечь. устар.*— судлашып бөлеп бетү, судлаша-судлаша бөлеп бетү.
**ПРОСУ'ЖИВАТЬ** *несов. просторечь.*— к. просудить.
**ПРОСУ'ЖИВАТЬСЯ** *несов. просторечь. устар.*— к. просудиться.
**ПРОСУ'НУТЬ** *сов.*— тыгу, сузу; *просунуть руку в отверстие* — кулны тишектән сузу.
**ПРОСУ'НУТЬСЯ** *сов.*— тыгылу, сузылу; *в дверь просунулась голова* — ишектән баш сузылды.
**ПРОСУТЯ'ЖИТЬ, ПРОСУТЯ'ЖНИЧАТЬ** *сов. просторечь.*— 1. дәгъвалаша-дәгъвалаша (берәр нәрсәдән) язу, колак кагу; *просутяжничать имущество* — дәгъвалашып мал-мөлкәтеннән язу; 2. (берникадәр вакыт) дәгъвалашу, дәгъвалашып (берникадәр вакытны) үткәрү.
**ПРОСУ'ШИВАТЬ** *несов.*— к. просушить.
**ПРОСУ'ШИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. просушиться; 2. *страд.* киптерелү.
**ПРОСУШИ'ТЬ** *сов.*— 1. киптерү; *просушить бельё* — кер киптерү; 2. (берникадәр вакыт) киптерү, киптереп (берникадәр вакытны) үткәрү.
**ПРОСУШИ'ТЬСЯ** *сов.*— кибү, кибеп житү.
**ПРОСУЩЕСТВОВА'ТЬ** *сов. книж.*— яшәү, тору (берникадәр вакыт).
**ПРОСЦЕ'НИУМ** *м.*— 1. *театр.* сәхнәнең алгы өлеше (пәрдәдән залга таба ягы); 2. *истор.* сәхнә (антик театрда).
**ПРОСЧЁ'Т** *м.*—1. *только ед. (действие)* к. просчитать 2; 2. *(ошибка в счёте)* хата, исәптә ялгышу, исәптәге ялгышлык.
**ПРОСЧИТА'ТЬ** *сов.*— 1. *разг.* санау, санап чыгу; *просчитай до ста* — йөзгә кадәр сана; *просчитай все деньги* — барлык акчаны санап чык; 2. санаганда (исәпләгәндә) ялгышып артык бирү, ялгыш санап артык бирү (акча турында); *кассир просчитал сто рублей* — кассир акча санаганда ялгышып йөз сум артык биргән; 3. (берникадәр вакыт) санау, санап тору, санап (берникадәр вакытны) үткәрү; *весь вечер просчитал на счётах* — кич буе счётта санадым, чут салдым.
**ПРОСЧИТА'ТЬСЯ** *сов.*— 1. ялгыш санап артык бирү; *кассир просчитался на десять рублей* — кассир ялгыш санап ун сум артык биргән; 2. *перен.* исәптә ялгышу; *враги просчитались* — дошманнар исәпләрендә ялгыштылар.
**ПРОСЧИ'ТЫВАТЬ** *несов.*— к. просчитать.
**ПРОСЧИ'ТЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. просчитаться; 2. *страд.* саналу, санап чыгылу.
**ПРО'СЫ'П** *м.*: без про́сыпу *разг.* — баш күтәрми, бертуктамый.
**ПРОСЫ'ПАТЬ** *сов.*— түгү, түгеп җибәрү, чәчү, чәчеп җибәрү.
**ПРОСЫПА'ТЬ** I *несов.*— к. проспать.
**ПРОСЫПА'ТЬ** II *несов.*— к. просы́пать.
**ПРОСЫ'ПАТЬСЯ** *сов.*— чәчелү, түгелү, чәчелеп китү, түгелеп китү.
**ПРОСЫПА'ТЬСЯ** I *несов.*— 1. к. проснуться; 2. *разг.* к. проспаться.
**ПРОСЫПА'ТЬСЯ** II *несов.* — к. просы́паться.
**ПРОСЫХА'ТЬ** *несов.*— к. просохнуть.
**ПРО'СЬБА** *ж.*— үтенеч, сорау.
**ПРОСЯ'НКА** *ж.*— тары чыпчыгы.
**ПРОСЯНО'Й** — тары...-ы; *просяная солома* — тары саламы.
**ПРОТА'ИВАТЬ** *несов.*— к. протаять.
**ПРОТА'ЛИНА** *ж.*— кары (бозы) эреп ачылган урын.
**ПРОТА'ЛКИВАТЬ** *несов.*— к. протолкать, протолкнуть.
**ПРОТА'ЛКИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. протолкнуться; 2. *страд.* төртеп кертелү (төшерелү), этеп-төртеп чыгарылу; төрткәләп кертелү (төшерелү), эткәләп-төрткәләп чыгарылу.
**ПРОТАНЦЕВА'ТЬ** *сов.*— 1. танцевать итеп алу, биеп алу; *протанцевать вальс* — вальс танцевать итеп алу; 2. (берникадәр вакыт) танцевать итү, бию, танцевать итеп (берникадәр вакытны) үткәрү, биеп үткәрү; *протанцевали до утра* — иртәнгә кадәр танцевать иттеләр.
**ПРОТА'ПЛИВАТЬ** *несов.*— 1. к. протопить; 2. *разг.* ягып алу, аз-азлап ягу; *печи протапливали лишь раз в неделю* — мичләрне атнасына бер тапкыр гына ягып алалар иде.
**ПРОТА'ПЛИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. протопиться; 2. *страд.* яхшылап ягылу, ягып җылытылу.
**ПРОТА'ПТЫВАТЬ** *несов.*— к. протоптать.
**ПРОТА'ПТЫВАТЬСЯ** *несов.*— к. протоптаться 1, 2, 3.
**ПРОТАРА'НИВАТЬ** *несов.*— к. протаранить.
**ПРОТАРА'НИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — таранлану, бәреп тишелү.
**ПРОТАРА'НИТЬ** *сов.*— 1. таранлау, бәреп тишү, бәреп тишеп чыгару; 2. *перен.* таранлау, фронтны өзү.
**ПРОТАРАТО'РИТЬ** *сов. разг.*— 1. такылдап алу, такылдап кую; 2. (берникадәр вакыт) такылдау, такылдап тору, такылдап (берникадәр вакытны) үткәрү; *протараторил весь день* — бөтен көнен такылдап үткәрде.
**ПРОТАРГО'Л** *м. мед.*— протаргол (дару).
**ПРОТАСКА'ТЬ** *сов. разг.*— 1. (берникадәр вакыт) күтәреп йөрү, күтәреп йөртү; *няня весь день протаскала ребёнка на руках* — бала караучы баланы көн буе

кулына күтәреп йөрде; 2. *фам.* сөйрәү, киеп йөрү; *эти брюки можно ещё целый месяц протаскать* — бу чалбарны тагы бер ай киеп йөрергә ярый әле; 3. *фам.* сөйрәп йөртү; *он с год протаскал его по судам* — ул аны бер елга якын судларга сөйрәп йөртте.

**ПРОТАСКА'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.*— 1. (берникадәр вакыт) йөрү, йөреп (берникадәр вакытны) үткәрү; *весь вечер протаскался по садам* — бөтен кичен бакчаларда йөреп үткәргән; 2. *простореч.* киелү, чыдау, түзү, җитү; *пальто не протаскалось и году* — пальто бер елга да чыдамады (тузды).

**ПРОТА'СКИВАТЬ** *несов.*— к. протащить, протаскать 1.

**ПРОТА'СКИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг. фам.* к. протащиться; 2. *страд.* сөйрәп алып барылу, өстерәп алып барылу, үткәрелү.

**ПРОТАЧА'ТЬ** *сов. спец.*— 1. *(тачая, прошить)* каеп чыгу; 2. (берникадәр вакыт) каю, каеп утыру, каеп (берникадәр вакытны) үткәрү.

**ПРОТА'ЧИВАТЬ** I *несов. спец.*— к. протачать.

**ПРОТА'ЧИВАТЬ** II *несов.*—к. проточить.

**ПРОТА'ЧИВАТЬСЯ** I *несов. страд. спец.*— каеп чыгылу.

**ПРОТА'ЧИВАТЬСЯ** II *несов. страд.*— 1. ашап тишкәләп бетерелү (мәсәлән, корт агачны); 2. юылу (су белән); 3. тишелү, кырып тишелү.

**ПРОТАЩИ'ТЬ** *сов.*— 1. *(мимо)* сөйрәп узу, өстерәп узу, сөйрәп алып китү, өстерәп алып китү; *(до какого-нибудь места)* сөйрәп алып бару (килү), өстерәп алып бару (килү); 2. чыгару, үткәрү; *рояль не протащить в эту дверь* — рояльне бу ишектән үткәреп булмас; 3. *разг. фам.* үткәрү; *протащить вредные идеи* — зарарлы идеяләр үткәрү; 4. *простореч. фам.* язып чыгу (тәнкыйтьләү мәгънәсендә); *протащить в газете* — газетага язып чыгу.

**ПРОТАЩИ'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.*— үтеп китү; *мимо нас протащился какой-то калека* — безнең яныбыздан ниндидер бер гарип кеше үтеп китте.

**ПРОТА'ЯТЬ** *сов.*— 1. эрү; эреп бетү; 2. (берникадәр вакыт) эрү.

**ПРОТЕЖЕ'** *м.* и *ж. нескл.* — протеже (протекция белән файдаланучы, кемнең дә булса канаты астында яшәүче).

**ПРОТЕЖИ'РОВАТЬ** *несов. устар. книжн.*— протекция күрсәтү, яклау, канат астына алу.

**ПРОТЕ'З** *м.*— протез (ясалма аяк, кул, теш һ. б.).

**ПРОТЕЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. спец.*— протез кую, протез ясап кую.

**ПРОТЕ'ЗНЫЙ** *спец.* — протез...-ы, протезлар...-ы, протез(лар) ясау...-ы; *протезная мастерская* — протезлар мастерское.

**ПРОТЁК** *м. обл.*— тишек.

**ПРОТЕКА'ТЬ** *несов.*— к. протечь.

**ПРОТЕ'КТОР** I *м. книжн. устар.*— протектор (протекция ясаучы; яклаучы, канат астына алучы).

**ПРОТЕ'КТОР** II *м. полит.*— протектор (протекторатны тормышка ашыручы капиталистик дәүләт).

**ПРОТЕКТОРА'Т** *м.*— протекторат (халыкара хокукта көчлерәк капиталистик дәүләткә көчсезрәк дәүләтләрне үзенә буйсындырырга мөмкинлек бирә торган бәйлелек формаларының берсе).

**ПРОТЕКЦИОНИ'ЗМ** I *м. мн.* нет, *экон.*— протекционизм (капиталистик илләрдә тышкы сәүдәдә чит илләрдән кертелә торган товарларга зур пошлиналар салып, үзләренең промышленностен үстерү һәм аны чит ил конкурентларыннан саклау политикасы).

**ПРОТЕКЦИОНИ'ЗМ** II *м. мн.* нет, *неодобр.* — протекционизм, протекция ясау, дус-ишләрне яклаучылык (хезмәттә агай-энелек, кода-кодагыйлык, әшнәлек мөнәсәбәтләре күрсәтү).

**ПРОТЕКЦИОНИ'СТ** *м. экон.*— протекционист, протекционизм тарафдары.

**ПРОТЕКЦИОНИ'СТСКИЙ** *экон.* — протекционизм...-ы; *протекционистская политика* — протекционизм политикасы.

**ПРОТЕКЦИО'ННЫЙ** *экон.* — к. протекционистский.

**ПРОТЕ'КЦИЯ** *ж.*— протекция (кемне дә булса яклау, канат астына алу, урынга урнаштыру яки хезмәттә күтәрү).

**ПРОТЕРЕ'ТЬ** *сов.*— 1. ышкып тишү, ышкый-ышкый тишеп чыгару, ышкып тишеп чыгару; *протёр рукава на локтях* — җиң терсәкләрен ышкый-ышкый тишеп чыгарган; 2. сөртеп чыгу, сөртеп чистарту; *протереть окна тряпкой* — тәрәзәләрне чүпрәк белән сөртеп чыгу; 3. кыру; *протереть картофель*—бәрәңге кыру. ◇ **Протереть глаза** *разг. фам.* — 1. күзләрне (йокыдан) ачу, йокыдан уяну; *дай протереть глаза* — күзләремне ачарга ирек бир; 2. *(о деньгах)* туздырып бетерү, типтереп бетерү.

**ПРОТЕРЕ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. ышкылып тишелү, ышкылып тишелеп бетү; *брюки протёрлись* — чалбар ышкылып тишелгән; 2. *простореч. неодобр.* тыкшыну, тыкшынып керү: *он незаметно протёрся в их компанию* — ул сиздермичә генә аларның компаниясенә тыкшынган; 3. *простореч. фам.* кысыла-кысыла үтү, тыкшынып үтү, кысылып үтү; *протёрся сквозь толпу* — халык төркеме арасыннан кысыла-кысыла үтте.

**ПРОТЕРПЕ'ТЬ** *сов. разг.*— (берникадәр вакыт) чыдау, түзү, чыдап тору, түзеп тору, сабыр итү.

**ПРОТЕСА'ТЬ** *сов. спец.*— 1. юнып ясау; *протесать паз* — юнып ырмау ясау; 2. (берникадәр вакыт) юну, (берникадәр вакытны) юнып үткәрү.

**ПРОТЕСНИ'ТЬСЯ** *сов.* — кысылып үтү, кысыла-кысыла чыгу (керү).

**ПРОТЕ'СТ** *м.* — протест, ризасызлык белдерү.

**ПРОТЕСТА'НТ** I *м. книж. устар.*— протест белдерүче, ризасызлык белдерүче.

**ПРОТЕСТА'НТ** II *м. рел.* — протестант (протестантлар динен тотучы).

**ПРОТЕСТАНТИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.*— протестантизм (XVI йөз реформация чорында католицизмнан аерылып чыккан дини тәгълиматлар, мәсәлән, кальвинизм, лютеранлык).

**ПРОТЕСТА'НТКА** *ж.*— к. протестант.

**ПРОТЕСТА'НТСКИЙ** — протестант...-ы; *протестантские исповедания*—протестант диннәре.

**ПРОТЕСТА'НТСТВО** *ср. мн.* нет, *рел.*— протестантлык, протестантизм.

**ПРОТЕСТОВА'ТЬ** *несов.*— 1. протест белдерү, ризасызлык белдерү; 2. *фин. торг.* протест ясау.

**ПРОТЕСТОВА'ТЬСЯ** *несов. страд. фин. торг.*— протест ясалу.

**ПРОТЁСЫВАТЬ** *несов. спец.*— к. протесать.

**ПРОТЁСЫВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— юнып ясалу.

**ПРОТЕ'ЧЬ** *сов.*— 1. *(о реке, ручье)* агу; 2. керү, саркып үтү, су үтү; *вода протекла в лодку* — көймәгә су кергән; *крыша в сарае протекла* — сарай түбәсеннән су үткән; 3. *перен.* узу, үтү; *день протёк быстро* — көн тиз үтте.

**ПРО'ТИВ** *предлог с род. п.*— 1. каршы; *сидеть против света* — яктыга каршы утыру; *действовать против неприятеля*— дошманга каршы хәрәкәт итү; 2. карата; *против отца у меня не было никакого дурного чувства* — атама карата минем һичнинди начар хисләрем юк иде; 3. ...-дан; *лекарство против ревматизма* — ревматизмнан дару; 4. караганда, чагыштырганда; *выпущено продукции больше против прошлого года* — продукция үткән елга караганда күбрәк житештерелгән.

**ПРО'ТИВЕНЬ** I *м.*— калай таба (калайдан ясалган дүрт почмаклы таба).

**ПРО'ТИВЕНЬ** II *м.*— 1. *обл. (противный ветер)* каршы жил; 2. *разг. устар. (один из пары одинаковых)* иш, сынар; 3. *спец. устар.* копия, күчермә.

**ПРОТИВИ'ТЕЛЬНЫЙ**: **противительный союз** *лингв.*— каршы куючы теркәгеч.

**ПРОТИ'ВИТЬСЯ** *несов. книж.*— карышу, каршылык күрсәтү, каршы тору.

**ПРОТИВЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж. устар.*— каршылык, каршылык күрсәтү.

**ПРОТИ'ВНИК** *м.*, **ПРОТИ'ВНИЦА** *ж.*— 1. дошман; *разбить противника* — дошманны тар-мар итү; 2. *спорт.* каршы як; 3. *в знач. сказ.* каршы кеше; *мы — противники религиозного дурмана* — без дин агуына каршы кешеләр.

**ПРОТИ'ВНО** *предлог с дат. п. книж.*— каршы.

**ПРОТИ'ВНЫЙ** I — 1. каршы; *противный ветер* — каршы жил; 2. дошман, каршы; *противные стороны* — каршы яклар; 3. *в знач. сущ.* кире; *утверждать противное*— киресен раслау. ◇ **В противном случае** — шулай булмаганда, әгәр шулай булмаса, югыйсә, киресенчә булганда.

**ПРОТИ'ВНЫЙ** II — күңел болгандыргыч, жирәнеч; *противный запах* — күңел болгандыргыч ис. ◇ **Мне (тебе, ему и т. д.) противно об этом слушать** — бу турыда мин тынлый алмыйм, күңелем болгана.

**ПРОТИВОБОЛЕВО'Й** *мед.* — авыртуны бетерә торган, авыртуны сиздерми торган.

**ПРОТИВОБО'РСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.*— каршы көрәш, каршы көрәшү.

**ПРОТИВОБО'РСТВОВАТЬ** *несов. книж.*— каршы көрәшү, каршы тору.

**ПРОТИВОВЕ'С** *м.*— каршылама (1. *тех.* каршы авырлык; 2. *радио* жиргә тоташтыргыч). ◇ **В противовес** — каршы буларак; *выдвинуть новое предложение в противовес оппоненту* — оппонентка каршы буларак яна тәкъдим кертү.

**ПРОТИВОВОЗДУ'ШНЫЙ** — һава һөжүменә каршы булган, һавадан булган һөжүмгә каршы.

**ПРОТИВОГА'З** *м.* — противогаз (агулаучы матдәләрдән саклый торган махсус прибор).

**ПРОТИВОГА'ЗОВЫЙ** — газдан саклану...-ы, газдан саклый торган; *противогазовые маски* — газдан саклый торган маскалар; *противогазовые средства* — газдан саклану чаралары.

**ПРОТИВОГЛИ'СТНЫЙ** *мед.* — глистларга каршы кулланыла торган, паразит суалчаннарга каршы кулланыла торган.

**ПРОТИВОГНИ'ЛОСТНЫЙ** *спец.* — черүдән саклый торган, черүгә каршы тора торган.

**ПРОТИВОДАВЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *тех.* — каршы басым, басымга каршылык (пар машинасында).

**ПРОТИВОДЕ'ЙСТВИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — каршылык, каршы көч (хәрәкәт); каршы тәэсир.

**ПРОТИВОДЕ'ЙСТВОВАТЬ** *несов. книж.*— каршы килү, каршылык күрсәтү, каршы чара күрү, каршы тору.

**ПРОТИВОЕСТЕ'СТВЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— табигый (нормаль) булмау, табигый түгеллек.

**ПРОТИВОЕСТЕ'СТВЕННЫЙ** *книж.*— табигый (нормаль) булмаган, табигатькә каршы булган.

**ПРОТИВОЗАКО'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— законга каршы булу, законга каршылык, законга сыймау.

**ПРОТИВОЗАКО'ННЫЙ** — законга каршы булган, законга сыймый торган.

**ПРОТИВОЗАЧА'ТОЧНЫЙ** *спец.* — бала булдырмый торган, балага узудан саклый торган.

**ПРОТИВОЛЕЖА'ЩИЙ** *мат.* — каршы ятучы, каршыдаш; *противолежащие углы* — каршы ятучы почмаклар.

**ПРОТИВОПОЖА'РНЫЙ** *спец.*— янгынга каршы (булган), янгын сүндерү...-ы, янгын сүндерү өчен кулланыла торган; *противопожарные меры* — янгынга каршы чаралар.

**ПРОТИВОПОКАЗА'НИЕ** *ср.*— 1. *право* капма-каршы күрсәтү, киресен күрсәтү (сөйләү); 2. *мед.* (даруның яки дәвалауның) зарарлы булуын күрсәтә торган билге, даруның (яки дәвалауның) килешмәвен күрсәтә торган билге.

**ПРОТИВОПОКА'ЗАННЫЙ** *мед.* — 1. зарарлы, зыянлы, ярамаган; 2. *в знач. сказ.* ярамый, зарарлы, зыянлы; *лечение этим средством для него противопоказано* — бу дару белән дәвалау аның өчен зарарлы.

**ПРОТИВОПОЛАГА'ТЬ** *несов. книж.*— к. противопоставлять.

**ПРОТИВОПОЛАГА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.*— каршы куелу.

**ПРОТИВОПОЛОЖЕ'НИЕ** *ср. книж.*— к. противопоставление.

**ПРОТИВОПОЛОЖИ'ТЬ** *сов. книж.*— к. противополагать.

**ПРОТИВОПОЛО'ЖНОСТЬ** *ж. книж.*— 1. каршылык, капма-каршылык, капма-каршы булу; 2. (бер-берсенә) капма-каршы кеше (әйбер); *Онегин и Ленский — две противоположности* — Онегин белән Ленский бер-берсенә капма-каршы кешеләр.

**ПРОТИВОПОЛО'ЖНЫЙ**—1. каршы, каршы яктагы; *противоположный берег* — каршы яктагы яр; 2. каршы, капма-каршы; *противоположное мнение* — капма-каршы фикер.

**ПРОТИВОПОСТА'ВИТЬ** *сов. книж.*— каршы кую.

**ПРОТИВОПОСТАВЛЕ'НИЕ** *ср. книж.*—к. противопоставить.

**ПРОТИВОПОСТАВЛЯ'ТЬ** *несов. книж.*— к. противопоставить.

**ПРОТИВОПОСТАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.*— каршы куелу.

**ПРОТИВОПРАВИ'ТЕЛЬСТВЕННЫЙ** *книж.*— хөкүмәткә каршы (булган).

**ПРОТИВОРЕЧИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — каршылыклылык, капма-каршы булу, каршылыклы булу.

**ПРОТИВОРЕЧИ'ВЫЙ** *книж.*— каршылыклы, капма-каршы килә торган.

**ПРОТИВОРЕ'ЧИЕ** *ср.*— каршылык.

**ПРОТИВОРЕ'ЧИТЬ** *несов. книж.*—1. *(возражать)* каршы килү, каршы әйтү, карулашу; 2. каршы килү, капма-каршы килү; *эти факты противоречат друг другу* — бу фактлар бер-берсенә капма-каршы киләләр.

**ПРОТИВОСИЯ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *астр.*— каршы балкыш (төнлә күкнең кояшка капма-каршы булган ноктасында барлыкка килә торган кечкенә генә яктылык).

**ПРОТИВОСТА'ТЬ** *сов. книж. редко* — к. противостоять.

**ПРОТИВОСТОЯ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *астр.*— каршы торыш (планетаның кояшка капма-каршы булган ноктада торышы).

**ПРОТИВОСТОЯ'ТЬ** *несов. книж.*— 1. *устар. (стоять напротив кого-чего-н.)* каршысында басып тору; 2. *(сопротивляться)* каршы тору, каршылык күрсәтү, чыдау, түзү; 3. капма-каршы тору; *этому мнению противостояло другое, более правильное* — бу фикергә икенче бер дөресрәк фикер капма-каршы тора иде (ягъни капма-каршы куелган иде).

**ПРОТИВОТА'НКОВЫЙ** *воен.*: **противотанковая оборона** — танк һөҗүменә каршы оборона; **противотанковая артиллерия** — танкка каршы артиллерия.

**ПРОТИВОХИМИ'ЧЕСКИЙ** — агулы газларга (матдәләргә) каршы, агулы газлардан (матдәләрдән) саклый торган.

**ПРОТИВОЦИНГО'ТНЫЙ** *мед.* — зәңгеләгә каршы, зәңгеләгә каршы кулланыла торган, зәңгеләдән кулланыла торган, зәңгеләдән саклый торган.

**ПРОТИВОЧУ'МНЫЙ** *мед.*—чумага (үләткә) каршы, чумага (үләткә) каршы кулланыла торган, чумадан (үләттән) кулланыла торган, чумадан саклый торган.

**ПРОТИВОЯ'ДИЕ** *ср.*— агу кайтаргыч, агуга каршы кулланыла торган дару.

**ПРОТИ'ВУ** *предлог с род п. устар.*— к. против.

**ПРОТИРА'ТЬ** *несов.*— к. протереть.

**ПРОТИРА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. протереться; 2. *страд.* сөртелү, сөртеп чыгылу, сөртеп чистартылу; 3. *страд.* кырылу.

**ПРОТИ'РКА** *ж. разг.*— 1. *только ед. (действие)* к. протереть; 2. *(тряпка для протирания)* чүпрәк.

**ПРОТИ'РОЧНЫЙ** *спец.*— сөртә торган, чистарта торган.

**ПРОТИ'РЩИК** *м. спец.*— 1. *(тот, кто прочищает)* сөртүче, сөртеп торучы; 2. изүче, изеп торучы; *протирщик белил* — ак буяу изүче.

**ПРОТИ'СКАТЬ** *сов. разг.*—этккәләп-төрткәләп кертү (чыгару).

**ПРОТИ'СКАТЬСЯ** *сов. разг.*— этешеп-төртешеп (керү) чыгу, этешеп-төртешеп үтү, кысыла-кысыла үтү, кысылып чыгу (керү), кысыла-кысыла чыгу (керү).

**ПРОТИ'СКИВАТЬ** *несов. разг.*— к. протиснуть, протискать.

**ПРОТИ'СКИВАТЬСЯ** *несов.*— к. протискаться.

**ПРОТИ'СНУТЬ** *сов. разг.*— тыгу, кертү, этеп-төртеп кертү (чыгару).

**ПРОТИ'СНУТЬСЯ** *сов. разг.*— к. протискаться.

**ПРОТКА'ТЬ** *сов.*— 1. *(выткать какой-н. нитью)* чүпләмләү, чүпләмләп туку; 2. туку, сугу; (тукыма) тукып (берникадәр вакытны) үткәрү; (киндер) сугып (берникадәр вакытны) үткәрү; *весь день проткала полотно* — көн буе киндер суктым.

**ПРОТКНУ'ТЬ** *сов.*— чәнчеп тишү, кадап тишү.

**ПРОТЛЕ'ТЬ** *сов.*— 1. *(прогореть, тлея)* пыскып янып бетү; 2. *(прогнить, тлея)* кызып череп бетү; 3. (берникадәр вакыт) пыскып яну, пыскып янып тору; 4. (берникадәр вакыт) кызып череп яту.

**ПРОТО...** — 1. теге я бу төшенчәнең беренчеллеген күрсәтү өчен шул сүзнең алдына кушыла торган кисәкчә, мәсәлән, прототип — беренчел яки үрнәк тип; 2. *бран. разг.* кире төшенчәдәге сүзләрнең иң югары яки чик дәрәҗәсен күрсәтү өчен кулла-

нысла торган кисәкчә, мәсәлән, *протоканалья* — үтә кабахәт, үтә алдакчы кеше.

**ПРОТОБЕ'СТИЯ** *ж. разг. бран.* — алдакчының да алдакчысы, хәйләкәрнең дә хәйләкәре, этнең дә эте, әрсезнең дә әрсезе.

**ПРОТОИСТОРИ'ЧЕСКИЙ** *науч.* — тарихкача булган.

**ПРОТОИСТО'РИЯ** *ж. науч.* — (кешелек дөньясының) тарихкача булган чоры.

**ПРОТО'К** *м.* — 1. *(рукав реки)* ермак; 2. *анат. (канал)* юл.

**ПРОТОКО'Л** *м.* — беркетмә, протокол.

**ПРОТОКОЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книжн.* — протоколизм, протокол стилендә язу.

**ПРОТОКОЛИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — 1. беркетмә (протокол) язу, беркетмәгә (протоколга) теркәү; 2. *перен.* беркетмә (протокол) стилендә язу (язып алу).

**ПРОТОКОЛИ'СТ** *м. офиц.* — беркетмә (протокол) язучы.

**ПРОТОКО'ЛЬНЫЙ** — беркетмә...-ы, протокол...-ы; *протокольный стиль* — беркетмә стиле.

**ПРОТОЛКА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. (төрткәләп) төшерү, (төртеп) төшерү; *протолкать пробку в бутылку* — бөкене шешә эченә (төртеп) төшерү; 2. эткәләп-төрткәләп чыгару; *протолкать кого-н. сквозь толпу* — кемне дә булса халык төркеме арасыннан эткәләп-төрткәләп чыгару.

**ПРОТОЛКА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *разг. (пройти, толкаясь)* этеп-төртеп узу (керү), ерып чыгу; 2. *просторeч.* эшсез йөреп (берникадәр вакытны) үткәрү, бушка йөреп үткәрү.

**ПРОТОЛКНУ'ТЬ** *сов.* — 1. төртеп кертү, төртеп төшерү; *протолкнуть пробку в бутылку* — бөкене шешә эченә (төртеп) төшерү; 2. этеп-төртеп чыгару; *протолкнуть кого-нибудь сквозь толпу* — кемне дә булса халык арасыннан этеп чыгару; 3. *перен. разг.* тизләтү, ход бирү; *протолкнуть дело* — эшне тизләтү.

**ПРОТОЛКНУ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — ерып чыгу.

**ПРОТОЛКОВА'ТЬ** *сов. разг.* — (берникадәр вакыт) сөйләшү, сөйләшеп тору, сөйләшеп (берникадәр вакытны) үткәрү.

**ПРОТОЛКО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. протолковать.

**ПРОТОМИ'ТЬ** *сов.* — 1. *разг.* (берникадәр вакыт) интектерү, интектереп тоту, талчыктыру, талчыктырып тоту, йөдәтү, йөдәтеп тоту, алҗыту, алҗытып тоту; зарыктыру, ялыктыру; 2. *кулин.* (берникадәр вакыт) талдыру; *протомить лук* — суган талдыру.

**ПРОТОМИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *разг.* интегеп тору, алҗып тору, зарыгу; 2. *кулин.* талу.

**ПРОТО'Н** *м. физ.* — протон (водород атомы төше составына керә торган унай корылмалы кисәкчек).

**ПРОТОНЕОЛИ'Т** *м. археол.* — протонеолит (палеолит белән неолит арасындагы чор).

**ПРОТОПИ'ТЬ** I *сов.* — 1. яхшылап ягу, ягып җылыту; *протопить печи* — мичләрне яхшылап ягу; 2. (берникадәр вакыт) ягу, ягып (берникадәр вакытны) үткәрү; *протопил печь целых четыре часа* — мич ягып дүрт сәгать вакытымны үткәрдем.

**ПРОТОПИ'ТЬ** II *сов.* — 1. эретеп җиткерү; *протопить сало* — мал маен эретеп җиткерү; 2. май эретеп (берникадәр вакытны) үткәрү; *два часа протопила масло* — ике сәгать вакытны май эретеп үткәрдем.

**ПРОТОПИ'ТЬСЯ** — узу, янып бетү; *печка протопилась* — мич янып бетте, мич узды.

**ПРОТОПЛА'ЗМА** *ж. биол.* — протоплазма (хайван һәм үсемлек организмы күзәнәкләренең нигезен тәшкил итә торган төп матдә).

**ПРОТОПТА'ТЬ** *сов.* — 1. күп йөреп (юл, сукмак) салу; *протоптать тропинку* — күп йөреп сукмак салу; 2. таптап кырып бетерү; *протоптать ковёр* — паласны таптап кырып бетерү; 3. *разг.* туздырып бетерү; тишеп бетерү; *протоптал подмётки* — олтаннарын туздырып бетергән.

**ПРОТОПТА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. күп йөрүдән (юл, сукмак) салыну; *протопталась широкая тропинка* — күп йөрүдән киң сукмак салынган; 2. тапталып кырылып бетү; *ковёр протоптался* — палас тапталып кырылып беткән; 3. тузып бетү, тишелеп бетү; *подмётки протоптались* — олтаннар тузып беткән; 4. *фам.* таптанып тору.

**ПРОТОРГОВА'ТЬ** *сов.* — 1. *просторeч.* сәүдәдән зыян күрү, сату итеп зыян күрү; *проторговать сто рублей* — сәүдәдән йөз сум зыян күрү; 2. (берникадәр вакыт) сату, сату итү, сату итеп тору, сатып тору; *проторговал неделю апельсинами* — бер атна буена әфлисун сатты.

**ПРОТОРГОВА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. сәүдә итә-итә бөлү, сату итә-итә бөлү; бөлгенлеккә төшү; *фирма совсем проторговалась* — сату итә-итә фирма бөтенләй бөлде; 2. (берникадәр вакыт) сатулашу, сатулашып тору; *проторговался битый час* — бер сәгать буе сатулашып тордым.

**ПРОТОРГО'ВЫВАТЬ** *несов. просторeч.* — к. проторговать 1.

**ПРОТОРГО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. проторговаться 1.

**ПРОТО'РЖКА** *ж. обл.* — (сәүдәдән килгән) зыян, зарар.

**ПРО'ТОРИ** *ед.* нет, *устар.* — чыгымнар, расходлар, зыяннар.

**ПРОТОРИ'ТЬ** *сов. разг.* — йөреп юл (сукмак) салу.

**ПРОТОРЯ'ТЬ** *несов. разг.* — к. проторить.

**ПРОТОТИ'П** *м. лит.* — прототип, төп үрнәк.

**ПРОТО'ЧИНА** *ж.* — 1. (*червоточина*) корт ашаган урын; 2. (*отверстие, промытое водой*) агым су ашаган тишек, су юып ясалган тишек; 3. *обл.* к. проток. 1; 4. *спец.* кашка (ат маңгаенда).

**ПРОТОЧИ'ТЬ** *сов.* — 1. *(о червях, насекомых)* ашап тишкәләп бетерү; 2. (*о текучей воде*) юдыру, еру; 3. (берникадәр вакыт) чарлау, кайрау, чарлап (берникадәр вакытны) үткәрү, кайрап үткәрү; *целый час проточил топор* — балта кайрап бер сәгать-

вакытымны үткәрдем; 4. *спец.* (*токарным инструментом*) тишү, кырып тишү.

**ПРОТО'ЧНЫЙ** — 1. агым...; *проточная вода* — агым су; 2. агым сулы; *проточный пруд* — агым сулы буа.

**ПРОТРА'ВА** *ж. спец.*— 1. *только ед.* к. протравить 1, 2, 3; 2. агу, агулагыч (күнне, агачны, йонны, буяласы яки маныласы тукыманы эшкәртүдә кулланыла торган химик препарат).

**ПРОТРАВИ'ТЕЛЬ** *м. с.-х.*— 1. (*вещество для протравливания*) агу, агулагыч; 2. орлык агулагыч (машина).

**ПРОТРАВИ'ТЬ** I сов.— 1. *спец.* кислота белән ашатып (бизәк) төшерү; *протравить узор на стволе ружья* — кислота белән ашатып мылтык көпшәсенә бизәк төшерү; 2. *спец.* агу (агулагыч) белән эшкәртү; *протравить кожу* — күнне агу белән эшкәртү; 3. *с.-х.* агулау; *протравить зерно формалином* — орлыкны формалин белән агулау; 4. (берникадәр вакыт) агулау, агулап (берникадәр вакытны) үткәрү; *весь день протравили зерно* — бөтен көнне орлык агулап үткәрдек; 5. (берникадәр вакыт) агу белән эшкәртү, агу белән эшкәртеп (берникадәр вакытны) үткәрү; *весь день протравили кожу* — бөтен көнне агу белән күн эшкәртеп үткәрдем.

**ПРОТРАВИ'ТЬ** II *сов. разг.*— 1. (берникадәр вакыт) эт өстерү, эт өстереп (берникадәр вакытны) үткәрү; *три часа протравили медведя* — өч сәгать вакытны аюга эт өстереп үткәрдек; 2. *разг.* (җәнлеккә эт өстереп) аулый алмый калу, буш калу; *весь день видели одного только зайца, и того протравили* — көн буена бер генә куян күрдек, аны да аулый алмый калдык.

**ПРОТРА'ВЛИВАТЕЛЬ** *м. спец.*— к. протрава 2.

**ПРОТРА'ВЛИВАТЬ** *несов.*— к. протравить.

**ПРОТРА'ВЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. кислота белән ашатып (бизәк) төшерелү; 2. агу (агулагыч) белән эшкәртелү; 3. *с.-х.* агулану.

**ПРОТРАВЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. протравить.

**ПРОТРАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — к. протравливаться.

**ПРОТРА'ВОЧНЫЙ** *спец.* — агулау...-ы; агулагыч...; *протравочная машина* — агулагыч машина.

**ПРОТРА'ВЩИК** *м. спец.*— 1. *с.-х.* агулаучы; 2. *спец.* агу (агулагыч) ясаучы.

**ПРОТРА'КТОР** *м. мор.* — протрактор (почмаклар үлчәү өчен транспортир тибындагы махсус прибор, судноның юлын картада билгеләүдә кулланыла).

**ПРОТРАНЖИ'РИТЬ** *сов. разг. фам.*— җилгә очыру, җилгә очырып бетерү, туздырып бетерү, типтереп бетерү, тотып бетерү (акчаны, милекне).

**ПРОТРЕЗВЕ'ТЬ** *сов. разг.*— к. протрезвиться.

**ПРОТРЕЗВИ'ТЬ** *сов.*— айныту (исерекне).

**ПРОТРЕЗВИ'ТЬСЯ** *сов.*— айну (исерек кеше турында).

**ПРОТРЕЗВЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. протрезвить.

**ПРОТРЕЗВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. протрезвиться; 2. *страд.* айнытылу.

**ПРОТРЕЩА'ТЬ** *сов.*— 1. *разг.* шатырдап кую, шытырдап кую; (*о кузнечике*) черелдәп кую; 2. *разг.* (берникадәр вакыт) шатырдау, шытырдау, шатырдап тору, шытырдап тору; (*о кузнечике*) черелдәү, черелдәп тору.

**ПРОТРИЕРОВА'ТЬ** *сов. с.-х.*— триерлау, триер аша үткәрү.

**ПРОТРУБИ'ТЬ** *сов.*— 1. (быргы) кычкыртып алу, (быргы) уйнатып алу; 2. хәбәр тарату, хәбәр сөйләп йөрү; *об этой новости протрубили всему городу* — бу яңа хәбәр турында бөтен шәһәр буенча сөйләп йөрделәр; 3. (берникадәр вакыт) быргы кычкырту, быргы кычкыртып (берникадәр вакытны) үткәрү. ◇ **Протрубить уши** — колакларны тондырып бетерү.

**ПРОТРУ'СИТЬ** *сов. разг.* — (берникадәр вакыт) куркып (шүрләп) бару, (куркып) тору; *всю дорогу протрусил* — юл буе куркып бардым.

**ПРОТРУСИ'ТЬ** I *сов. разг.*— 1. (*о лошади*) юыртып үтеп китү; (*о человеке*) вак-вак атлап үтеп китү; 2. (берникадәр вакыт) юыртып бару.

**ПРОТРУСИ'ТЬ** II *сов. простореч.*— (селкеп бушатканда) читкә кою, читкә чәчү, читкә түгелү; *протрусил много муки* — онны (капчыктан) бушатканда читкә күп койган.

**ПРОТРУСИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.*— (селкеп бушатканда) читкә коелу, читкә чәчелү, читкә түгелү.

**ПРОТРЯСТИ'** *сов. разг.*— 1. кагу, селкетү; *в телеге его изрядно протрясло* — аны арба бик нык селкеткән; 2. (*о лихорадке*) калтырату, тоту (берникадәр вакыт).

**ПРОТРЯСТИ'СЬ** *сов. разг.*— 1. селкенеп бару, кагыла-сугыла бару; *протрястись в телеге всю дорогу* — юл буе арбада селкенеп бару; 2. *фам.* (акчаны) тотып бетерү, расходлану.

**ПРОТРЯ'ХИВАТЬ** *несов. разг.*— к. протряхнуть.

**ПРОТРЯХНУ'ТЬ** *сов. разг.*— тузанын кагып чыгару; *протряхнуть одежду* — киемнең тузанын кагып чыгару; киемнәрне кагып чыгу.

**ПРОТУБЕРА'НЦЫ** *мн. астр.*— протуберанец (кояш өслегенә атылып чыккан югары температуралы газлар).

**ПРОТУРИ'ТЬ** *сов. простореч. фам.*— куып җибәрү, куып чыгару, сөреп чыгару.

**ПРОТУХА'ТЬ** *несов.*— ислану, сасу, бозылып ислану, сөрсү, исләнеп (сасып, сөрсеп) бетү.

**ПРОТУ'ХЛОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.*— исләнгәнлек, сасыганлык, бозылганлык, сөрсегәнлек.

**ПРОТУ'ХЛЫЙ** *разг.*— исләнгән, сасыган, бозылган, сөрсегән.

**ПРОТУ'ХНУТЬ** *сов.*— к. протухать.

**ПРОТЫ'КАТЬ** *сов. разг.*— 1. (чәнчеп) тишкәләп бетерү; *всю доску протыкал* — бөтен тактаны тишкәләп бетергән; 2. тишкәләү, тишекләр ясау; *протыкал несколько*

*дыр в доске* — тактада берничә тишек ясаган; 3. *простореч.* (берникадәр вакыт) тишкәләү, тишкәләп утыру, тишкәләп (берникадәр вакытны) үткәрү.

**ПРОТЫКА'ТЬ** *несов.*— к. проткнуть.

**ПРОТЫ'КАТЬСЯ** *сов. простореч.*— (берникадәр вакыт) абынып-сөртенеп йөрү.

**ПРОТЫКА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— чәнчеп тишелү.

**ПУСТИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — башлау, керешү; *пуститься бежать* — йөгерә башлау. ◇ **Пуститься в дорогу, пуститься в путь** — юлга чыгу, юлга чыгып китү, сәфәргә чыгу.

**ПУ'СТО** — буш. ◇ **То густо, то пусто или разом густо, разом пусто** *разг.* — бар чакта бүредәй, юк чакта шүредәй.

**ПУСТОБРЁХ** *м. простореч.* — 1. *охот.* урынсызга өрә торган эт, токтымалга өрә торган эт; 2. *перен. пренебр. фам.* бушбугаз, лыгырдык.

**ПУСТОВА'ТЫЙ** *разг. фам.* — к. пустой 1.

**ПУСТОВА'ТЬ** *несов. разг.* — буш тору, буш яту, бушап тору.

**ПУСТОГОЛО'ВЫЙ** *разг. пренебр.* — төпсез, буш (кеше), кибәк баш.

**ПУСТОДО'М** *м. разг. устар.* — хәстәрсез, гамьсез, ваемсыз (хуҗа).

**ПУСТОЗВО'Н** *м. разг. фам.* — бушбугаз, лыгырдык; гайбәтче.

**ПУСТОЗВО'НИТЬ** *несов. разг. фам.* — юк-бар сүз (хәбәр) тарату, лыгырдау, сафсата сату.

**ПУСТОЗВО'ННЫЙ** *разг. фам.* — буш, эчтәлексез, мәгънәсез.

**ПУСТОЗВО'НСТВО** *ср. мн.* нет, *разг.* — бушбугазлык.

**ПУСТО'Й** — 1. буш; *пустая бочка* —

буш мичкә; 2. куыш, эче буш; *пустой шар* — куыш шар; 3. *перен.* буш, мәгънәсез; *пустое слово* — буш (мәгънәсез) сүз; 4. эчтәлексез; *пустая книга* — эчтәлексез китап; 5. *в знач. сущ.* юк нәрсә; *не верь ей: всё пустое* — ышанма анар: боларның барысы да юк нәрсә. ◇ **Пустые щи** — итсез щи, кысыр аш. **Пустое место** *перен. разг.* — мәгънәсез кеше, буш кеше. **Чтоб тебе (ему, вам, им) пусто было** *простореч.* — дөмеккере, җәһәннәмгә киткере. **Переливать из пустого в порожнее** — юкны бушка аудару.

**ПУСТОМЕ'ЛЯ** *м.* и *ж. разг. фам.* — бушбугаз, лыгырдык, буш сүзле кеше, сүз тегермәне.

**ПУСТОПОРО'ЖНИЙ** *разг.* — 1. буш; *пустопорожний участок* — буш участок; 2. *перен.* буш, кирәкмәгән, кирәксез, мәгънәсез, эчтәлексез.

**ПУ'СТОРОСЛЬ** *ж. мн.* нет, *собир. обл.* — сирәк куаклык, урмансыз җир.

**ПУСТОСЛО'В** *м. разг.* — к. пустомеля.

**ПУСТОСЛО'ВИЕ** *ср. мн.* нет — ләчтит, юк-бар сүзләр.

**ПУСТОСЛО'ВИТЬ** *несов. разг.* — ләчтит сату, лыгырдау, юк-барны сөйләү, чүбек чәйнәү.

**ПУСТОТА'** *ж.* — 1. бушлык; куыш; 2. өметсезлек, мәгънәсезлек, рухи бушлык.

**ПУСТОТЕ'ЛЫЙ** *тех.* — куыш.

**ПУСТО'ТНЫЙ** *тех.* — һавасыз, буш.

**ПУСТОЦВЕ'Т** *м.* — 1. *бот.* буш чәчәк, кысыр чәчәк; 2. *перен. книж.* мәгънәсез, юньсез, булдыксыз кеше.

**ПУСТОШИ'ТЬ** *несов. устар.* — к. опустошать.

**ПУСТО'ШКА** *ж. зоол.* — һөд-һөд (кош).

**ПУ'СТОШЬ** *ж.* — ташландык җир, буш җир.

**ПУСТЫ'ННИК** *м.*, **ПУСТЫ'ННИЦА** *ж. книж.* — дәрвиш (чүлдә ялгыз яшәүче кеше).

**ПУСТЫ'ННИЧЕСКИЙ** *книж.* — дәрвиш..-ы, дәрвишләр...-ы; дәрвишләрчә... ; *пустыннический образ жизни* — дәрвишләрчә көнкүреш.

**ПУСТЫННОЖИ'ТЕЛЬ** *м. церк. устар.* — к. пустынник.

**ПУСТЫННОЖИ'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет, *церк. устар.* — дәрвишләр тормышы, дәрвишлек.

**ПУСТЫ'ННЫЙ** — 1. сахра...-ы, | чүл...-ы, сахрада..., чүлдә...; *про жизнь пустынную* — чүл тормышы турында; 2. кешеләр яшәми торган; *пустынный остров* — кешеләр яшәми торган утрау; 3. аулак, тын, кешесез; *пустынные улицы* — тын урамнар.

**ПУСТЫ'НЬ** *ж.* — монастырь (кеше яшәми торган җирдәге).

**ПУСТЫ'НЯ** *ж.* — сахра, чүл.

**ПУСТЫ'РЬ** *м.* — буш җир, буш йорт урыны, ташландык урын.

**ПУСТЫ'ШКА** *ж. разг.* — 1. (*полый предмет*) эче куыш әйбер; 2. (*соска для детей*) имезлек; 3. *перен. фам.* (*о человеке*) буш кеше, мәгънәсез кеше.

**ПУСТЬ** — 1. *частица*...-сын, ...-а бирсен; *пусть придёт* — килсен; 2. *союз* (*при наличии союза „но" в главном предложении*) ярар...-кан да булыйм; *пусть я ошибся, но эту ошибку я давно исправил* — ярар, мин ялгышкан да булыйм, ләкин ул хатаны күптән инде төзәттем; 3. ...-гына булса да; *горе, пусть самое небольшое, трудно переносить* — кечкенә генә булса да кайгыны кичерүе авыр; 4. *частица* ярар, хәерле булсын, барыбер; *ну пусть, я согласен* — я ярар, мин ризамын; ярар соң, мин риза. ◇ **Пусть так** — ярар, шулай (да) булсын. **Пусть его** — әйдә...-сын, әйдә...-а бирсен; *пусть его идёт* — әйдә бара бирсен.

**ПУСТЯ'К** *м. разг.* — 1. юк-бар нәрсә; әһәмиятсез әйбер (нәрсә), вак-төяк, чүп-чар; *заниматься пустяками* — юк-бар нәрсәләр белән шөгыльләнү; *подарил какой-то пустяк* — ниндидер әһәмиятсез нәрсә бүләк итте; 2. *преимущ. мн. в знач. сказ. разг.* зарар юк; *нет, пустяки, я не ушибся* — зарар юк, мин имгәнмәдем. ◇ **Пара пустяков!** *простореч. фам.* — бик җиңел! берни түгел!

**ПУСТЯКО'ВИНА** *ж. простореч. фам.* — к. пустяк.

**ПУСТЯКО'ВЫЙ** *разг. фам.* — кечкенә, әһәмиятсез, вак-төяк, юк-бар.

**ПУСТЯ'ЧНЫЙ** *разг. фам.* — к. пустяковый.

**ПУСТЯЧО'К** *м. разг. пренебр.* — к. пустяк 1.

**ПУ'ТАНИК** *м. разг. пренебр.* — чуалчыклар кертүче, чуалтучы, буталчыклар кертүче, буташтыручы.

**ПУ'ТАНИЦА** *ж. мн.* нет, *разг.* — чуалчык, буталчыклык.

**ПУ'ТАНЫЙ** *разг.* — чуалчык, буталчык.

**ПУ'ТАТЬ** *несов.* — 1. чуалту, чәбәләндерү; *путать нитки* — җепне чуалту; 2. бутау, буташтыру, саташтыру, ялгышу, ялгыштыру; *я всегда их путаю* — мин һәрвакыт аларны бутыйм; *он что-то тут путает* — ул нидер монда бутый (ялгыша); *не путайте меня в это дело* — мине бу эшкә бутамагыз; 3. тышаулау; *путать лошадей* — атларны тышаулау; 4. *обл.* (*ходить, плутая*) адашып йөрү.

**ПУ'ТАТЬСЯ** *несов.* — 1. бутау, буталу, буташтыру, саташтыру; *путаясь, рассказывать* — бутала-бутала сөйләү; 2. чуалу; *мысли её путались* — аның фикерләре чуала иде; 3. *разг.* тыгылу, катнашу; *путаться не в своё дело* — кеше эшенә тыгылу; 4. *простореч.* буталып йөрү; *путаться в чужой комнате* — кеше бүлмәсендә буталып йөрү; 5. *разг.* (*ходить, плутая*) адашып йөрү; 6. *страд.* чуалтылу, чәбәләндерелү; буташтырылу.

**ПУТЕВИ'К** *м. спец.* — к. путеец.

**ПУТЁВКА** *ж.* — путёвка (1. берәр хезмәткә, эшкә яки ял йортына баручыга бирелә; 2. *спец.* транспорт йөртүчеләрдә маршрутны һәм үтәлә торган эшне күрсәтә торган документ, листок).

**ПУТЕВОДИ'ТЕЛЬ** *м. книж.* — 1. *устар.* (*руководитель*) житәкче, юл күрсәтүче; 2. (*книга*) юл күрсәткеч.

**ПУТЕВОДИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — к. путеводный.

**ПУТЕВО'ДНЫЙ** *книж.* — юл күрсәтүче, юл күрсәтә торган.

**ПУТЕВО'Й** — юл...-ы; *путевые расходы* — юл расходлары.

**ПУТЕ'ЕЦ** *м. разг.* — тимер юл эшчесе.

**ПУТЕ'ЙСКИЙ** *разг.* — юл...-ы, тимер юл...-ы; *путейский инженер* — юл инженеры.

**ПУТЁМ** I *нареч. разг.* — рәтләп, яхшылап.

**ПУТЁМ** II *предлог с род. п. книж.* — ...-ып,...юлы белән; *узнать путём опроса* — сорашып белү.

**ПУТЕПРОВО'Д** *м.* — юл үткәргеч (бер юл өстеннән аркылы чыга торган икенче бер юлның күпере).

**ПУТЕУКЛА'ДКА** *ж. мн.* нет, *тех.* — (тимер юл төзегәндә) рельс салу.

**ПУТЕУКЛА'ДОЧНЫЙ** *тех.* — (тимер юл төзегәндә) рельс салу...-ы; *путеукладочный поезд* — рельс салу поезды.

**ПУТЕУКЛА'ДЧИК** *м. тех.* — (тимер юл төзегәндә) рельс салучы.

**ПУТЕШЕ'СТВЕННИК** *м.*, **ПУТЕШЕ'СТВЕННИЦА** *ж.* — сәяхәтче, илгизәр.

**ПУТЕШЕ'СТВИЕ** *ср.* — 1. сәяхәт; *путешествие на Памир* — Памирга сәяхәт; 2. *лит.* сәяхәтнамә.

**ПУТЕШЕ'СТВОВАТЬ** *несов.* — 1. сәяхәт итү, ил гизү; 2. *разг. шутл.* (*ходить, бродить*) йөрү, йөреп тору.

**ПУТИ'НА** *ж.* — 1. *спец.* путина, балык тоту сезоны (вакыты); 2. *нар.-поэт.* (*путь*) юл; 3. *нар.-поэт.* (*путешествие*) сәяхәт.

**ПУТИ'ННЫЙ** *спец.* — путина...-ы, балык тоту...-ы, балык тоту вакытында кулланыла торган, путина вакытында кулланыла торган.

**ПУ'ТЛИЩЕ** *ср. спец.* — 1. өзәңге каешы; 2. *обл.* (*путы*) тышау.

**ПУТЛО'** *ср. спец. обл.* — к. путлище.

**ПУТЛЯ'ТЬ** *несов. простореч.* — 1. (*делать путла*) өзәңге каешлары ясау; тышаулар ясау; элмәкләр ясау; 2. *охот.* эзен бутап йөрү.

**ПУ'ТНИК** *м.*, **ПУ'ТНИЦА** *ж. книж.-поэт.* — юлчы, юлаучы.

**ПУ'ТНЫЙ** *разг.* — булдыклы, эшлекле, юньле; *путный человек* — булдыклы кеше. ◇ **Ничего путного не выйдет** (или **не получится**) — мәгънә чыкмас, рәт чыкмас; *я, признаюсь, не думал, чтобы из тебя вышло что-нибудь путное* — дөресен әйткәндә, мин синнән рәт чыгар (мәгънә чыгар) дип уйламаган идем.

**ПУ'ТО** *ср.* — к. путы.

**ПУТОВО'Й** *спец.*: **путовая кость** — бәкәл.

**ПУТЧ** *м. полит.* — путч, фетнә (бер төркем заговорчыларның дәүләт переворогы ясарга маташуы).

**ПУТЧИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *полит.* — путчизм, фетнәчелек (путчлар оештыру политикасы).

**ПУТЧИ'СТ** *м. полит.* — фетнәче.

**ПУ'ТЫ** *мн.* — 1. (*кандалы*) богау, зынҗыр; 2. *обл.* (*для лошадей*) тышау.

**ПУТЬ** *м.* — юл. ◇ **Счастливого пути** — хәерле юл, юлың уңсын, юлына ак җәймә. **Путь-дорога** *нар.-поэт.* — 1. юл; 2. хәерле юл. **По пути** — к. **по дороге**. **Без пути** *разг. фам.* — юкка, кирәксезгә. **Пути сообщения** — аралашу юллары (тимер юллар, су юллары, һава юллары). **Путь держать** — бару, юнәлү. **Ни путь, ни дело** *обл.* — ни ары, ни бире; юкка, нәтиҗәсез. **Млечный путь** — Киек каз юлы, Сөт юлы. **Быть на пути** *к чему.-н. перен.* — якынлашу, якынлашып килү. **Стоять поперёк пути** *кому-н.* — юлга аркылы яту, киртә булып тору, комачаулау. **Наставить на путь истинный** — к. наставить. **Сбиться с пути** — юлдан язу, адашу. **В нём пути не будет** *простореч.* — аннардан рәт чыкмас. **Во время пути** — юлда, юлда чакта.

**ПУФ** *м.* — 1. пуф (йомшак утыргычлы артсыз урындык, табурет); 2. *порт.* пуф, сыр; 3. (*ложное известие, выдумка*) уйдырма, куык, ялган хәбәр.

**ПУХ** *м. мн.* нет — 1. мамык; 2. *перен.* бала йоны. ◇ **Рыльце в пуху** (или **в пушку**) *разг. фам.* — гаебе бар, катнашы бар. **В пух и прах** *разг.* — көлен күккә очыру, пыран-заран китерү, пыр туздыру. **Ни пуха, ни пера** *разг.* — уңышлыклар телим.

**ПУ'ХЛОСТЬ** *ж. мн.* нет — кабарып тору, кабарып торганлык.

**ПУ'ХЛЫЙ** — кабарып торган, кабарынкы.

**ПУХЛЯ'ВЫЙ** *разг. фам.* — к. пухлый.

**ПУ'ХНУТЬ** *несов.* — шешенү, шешү, кабару. ◇ **Голова пухнет** *перен* — башым ярыла.

**ПУХОВИ'К** *м.* — мамык түшәк.

**ПУХО'ВКА** *ж.* — пудра сөрткеч, кершән яккыч.

**ПУХО'ВЫЙ** — мамык..., мамыктан ясалган; *пуховая перина* — мамык түшәк.

**ПУХОЕ'Д** *м. зоол.* — мамыкашар (хайваннарда һәм кошларда була торган паразит бөҗәк).

**ПУЧЕГЛА'ЗИЕ** *ср. мн.* нет, *мед.* — акай(ган) күзлелек (авыру билгесе).

**ПУЧЕГЛА'ЗИК** *м.*, **ПУЧЕГЛА'ЗКА** *ж. разг. фам.* — акай(ган) күзле (кеше).

**ПУЧЕГЛА'ЗЫЙ** *разг. фам.* — акай(ган) күзле.

**ПУЧИ'НА** *ж.* — упкын, чоңгыл.

**ПУ'ЧИТЬ** *несов. безл. разг.* — 1. *безл.* күтәрелү; *начало лёд пучить на реках* — елгаларда боз күтәрелә башлады; 2. *безл.* кубү; күптерү, кабарту; *живот пучит* — эч кубә. ◇ **Глаза пучить** *фам.* — күзләрне акайту, күзләрне шар итү.

**ПУ'ЧИТЬСЯ** *несов. разг.* — күтәрелү; кубү.

**ПУЧКОВА'ТЫЙ** *спец.* — бәйләмле, бәйләм-бәйләм.

**ПУЧО'К** *м.* — 1. бер кечкенә тотам, бер кечкенә бәйләм, учма; *пучок трав* — бер кечкенә тотам үлән; 2. *перен.* көлтә, бәйләм; *пучок лучей* — нурлар көлтәсе, нурлар бәйләме.

**ПУШБО'Л** *. спорт.* — пушбол (зур күн туп белән уйнала торган спорт уены).

**ПУ'ШЕЧНЫЙ** — пушка...-ы, туп...-ы; *пушечное ядро* — туп ядрәсе.

**ПУШИ'НКА** *ж.* — мамык бөртеге, бер бөртек мамык.

**ПУШИ'СТЫЙ** — 1. йомшак йонлы; *пушистый кот* — йомшак йонлы мәче; 2. мамыктай йомшак; *пушистые волосы* — мамыктай йомшак чәч.

**ПУШИ'ТЬ** *несов.* — 1. тетү, язу; *пушить шерсть* — йон тетү; 2. кабарту, тырпайту; *курица пушит перья* — тавык йонын тырпайта; 3. *перен. разг. фам. (упрекать, бранить)* тетмәсен тетү (битәрләү, тиргәү мәгънәсендә).

**ПУШИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *страд.* тетелү; кабартылу; 2. кабару, кабарып тору, күпереп тору.

**ПУШИ'ЦА** *ж. бот.* — мамыкбаш.

**ПУ'ШКА** I *ж.* — туп, пушка. ◇ **Пушкой не прошибёшь** *разг.* — 1. бик күп халык; 2. үз сүзле, кирегә беткән.

**ПУ'ШКА** II *ж. простореч.* — ялган; *это — пушка* — бу ялган. ◇ **Получить на пушку** *простореч. неодобр.* — алдаулы юл белән алу (кулга төшерү). **На пушку взять (когонибудь)** *простореч. неодобр.* — алдау.

**ПУШКА'РЬ** *м. воен. истор.* — тупчы (1. *простореч.* артиллерист; 2. *старин.* туплар кою остасы).

**ПУШКИНИ'СТ** *м. лит.* — Пушкин иҗатын өйрәнүче (әдәбиятчы).

**ПУШНИ'НА** *ж. мн.* нет, *собир.* — пушнина, җәнлек тиреләре; мех товарлары.

**ПУШНО'Й** — 1. кыйммәтле мехлы, кыйммәтле мех бирә торган; *пушной зверь* — кыйммәтле мех бирә торган җәнлек; 2. кыйммәтле мех..., кыйммәтле мех...-ы; *пушной товар* — кыйммәтле мех товар; *пушной промысел* — кыйммәтле мех промыселы.

**ПУШО'К** *м. мн.* нет, *разг.* — к. пух.

**ПУШО'НКА** *ж. хим. тех.* — сүндерелгән известь.

**ПУ'ЩА** *ж.* — кара урман, куе урман, куелык.

**ПУЩА'Й** *обл.* — к. пускай.

**ПУЩА'ТЬ** *несов. обл.* — к. пускать.

**ПУ'ЩЕ** *нареч. простореч.* — бигрәк тә, көчлерәк, ныграк, күбрәк; *ещё пуще рассердился* — тагы да ныграк ачуланды. ◇ **Пуще всего** — барысыннан да бигрәк.

**ПУ'ЩИЙ: для пущей важности** *разг.* — әһәмиятен арттырып күрсәтер өчен, кыйммәтен күтәрер өчен, әһәмиятлерәк итеп күрсәтер өчен.

**ПХАТЬ** *несов. простореч.* — к. пихать.

**ПХНУТЬ** *сов. простореч.* — к. пихнуть.

**ПЧЕЛА'** *ж.* — умарта корты, бал корты.

**ПЧЕЛИ'НЫЙ** — умарта корты...-ы, бал корты...-ы; *пчелиный мёд* — умарта корты балы.

**ПЧЕЛОВО'Д** *м.* — умартачы, умартачылык белгече.

**ПЧЕЛОВО'ДНЫЙ** *с.-х.* — умартачылык...-ы; *пчеловодный инвентарь* — умартачылык инвентаре.

**ПЧЕЛОВО'ДСТВО** *ср.* — умартачылык, умарта асраучылык, кортчылык.

**ПЧЕЛОВО'ДЧЕСКИЙ** — умартачылар...-ы, умартачылык...-ы, кортчылык...-ы; *пчеловодческое хозяйство* — умартачылык хуҗалыгы; *пчеловодческие курсы* — умартачылар курсы.

**ПЧЕ'ЛЬНИК** *м.* — умарталык.

**ПЧЕ'ЛЬНЫЙ** *спец.* — умартачылык...-ы; *пчельный промысел* — умартачылык промыселы.

**ПЧЕЛЯ'К** *м. обл.* — к. пчеловод.

**ПШЕНИ'ЦА** *ж. мн.* нет — бодай.

**ПШЕНИ'ЧКА** *ж.* — 1. к. пшеница; 2. *обл.* кукуруз.

**ПШЕНИ'ЧКОВЫЙ** *обл.* — кукуруз...-ы; *пшеничковая лепёшка* — кукуруз күмәче.

**ПШЕНИ'ЧНЫЙ** — бодай...-ы; *пшеничная мука* — бодай оны.

**ПШЁ'НКА** *ж.* — 1. *обл.* к. пшённичка 2; 2. *разг.* тары боткасы.

**ПШЁ'ННИК** *м. разг.* — 1. к. пшёнка 2; 2. *обл.* тары икмәге.

**ПШЁ'ННЫЙ** — тары...-ы; *пшённая каша* — тары боткасы.

**ПШЕНО'** *ср. мн.* нет — тары ярмасы.

**ПШИК** *м. разг. фам.*: **окончиться пшиком** — нәтиҗәсез бетү; **останется один пшик** — һичбер нәрсә калмас.

**ПШЮТ** *м. разг. пренебр. устар.* — җилкуар, кием калыбы.

**ПШЮТОВА'ТЫЙ** *разг. пренебр. устар.* — җилкуар..., җилкуарга охшаган; *пшютоватый юнец* — җилкуар егет.

**ПЫЖ** *м.* — 1. тыккыч (патронга, элекке ау мылтыкларына дары тутырганда тыгып куела торган йомарланган йон, киндер сүсе); 2. *обл.* бөке, чөмәк, тыккыч; 3. *обл.* кысыр орлык (шытмый торган орлык).

**ПЫ'ЖИК** *м.* — 1. *разг. фам.* карсак юан кеше; 2. *обл.* яшь болан; 3. *спец.* яшь болан мехы.

**ПЫ'ЖИТЬСЯ** *несов. простореч.* — 1. *(важничать)* тәкәбберләнү, һаваланү, кәпрәю, үзен эре тоту; борын күтәрү; 2. *(стараться изо всех сил)* көчәнү, тырышу.

**ПЫЛ** *м. мн.* нет — 1. *обл. (пламя)* ялкын; 2. *перен. книж.* дәрт, ялкын; *юношеский пыл* — яшьлек дәрте, яшьлек ялкыны. ◇ **В пылу гнева** — ачу катыш, ачу килгән килеш. **В пылу (сраженья, спора и т. п.)** *книж.* — (бәхәснең, сугышның һ. б.) кызу чагында, кызган чагында.

**ПЫЛА'ТЬ** *несов. книж.* — 1. ялкынланып яну, дөрләп яну; *дрова пылают* — утын дөрләп яна; 2. балку, ялтырау; *зал пылает тысячами огней* — зал меңнәрчә утлар белән балкый; 3. *перен.* яну, кызарып янып тору; *пылают щёки* — яңаклары кызарып янып тора; 4. *перен.* ...утында яну; *пылает гневом* — ачу утында яна.

**ПЫЛЕВИ'ДНЫЙ** *спец.* — тузансыман, порошоксыман.

**ПЫЛЕВСА'СЫВАЮЩИЙ** *тех.* — тузан суыра торган, тузан җыя торган.

**ПЫЛЕНЕПРОНИЦА'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *спец.* — тузан үткәрмәү(чәнлек).

**ПЫЛЕНЕПРОНИЦА'ЕМЫЙ** *спец.* — тузан үткәрми (кертми) торган.

**ПЫЛЕОТСА'СЫВАЮЩИЙ** *спец.*— тузан суыргыч..., тузаннан чистарта торган.

**ПЫЛЕОЧИСТИ'ТЕЛЬ** *м. тех.* — 1. тузан чистарткыч; 2. к. пылеуловитель.

**ПЫЛЕСО'С** *м.*— тузан суыргыч.

**ПЫЛЕУЛОВИ'ТЕЛЬ** м. *тех.*—тузан суыргыч, тузан җыйгыч, тузан тоткыч.

**ПЫЛИ'НКА** *ж.*— 1. *разг.* тузан, тузан бөртеге; 2. *бот.* к. пыльца.

**ПЫЛИ'ТЬ** *несов.*— тузан туздыру, тузан чыгару.

**ПЫЛИ'ТЬСЯ** *несов.*— тузанлану, тузан җыну.

**ПЫ'ЛКИЙ** — 1. *обл.* кызу яна торган, дөрләп яна торган; *пылкие дрова* — кызу яна торган утын; 2. кызу; *пылкий огонь* — кызу ут; 3. *книж.* ялкынлы, ярсулы, дәртле; *пылкая юность*— ялкынлы яшьлек; 4. *книж.* кайнар; *пылкая любовь* — кайнар мәхәббәт.

**ПЫ'ЛКОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— дәртлелек, ялкын.

**ПЫЛЬ** *ж. мн.* нет — тузан. ◇ **Пыль в глаза пускать** (пустить) *разг.*— к. глаз.

**ПЫ'ЛЬНИК** *м.*—1. *бот.* серкәлек; 2. *разг.* пыльник, плащ.

**ПЫЛЬНО'Й** — тузан...-ы; тузан сөртә торган; *пыльная тряпка* — тузан сөртә торган чүпрәк.

**ПЫ'ЛЬНЫЙ** — 1. тузанлы; 2. *разг.* к. пыльной.

**ПЫЛЬЦА'** *ж. мн.* нет, *бот.*— серкә.

**ПЫРЕ'Й** *бот. с.-х.*— сарут, актамыр.

**ПЫРЕ'ЙНИК** *м. бот. с.-х.*— сарут, актамыр; сарут сабагы, актамыр сабагы.

**ПЫРНУ'ТЬ** *сов. простореч.*— 1. чәнчү; 2. (*о корове*) сөзү.

**ПЫРЯ'ТЬ** *несов. простореч.*— к. пырнуть.

**ПЫТА'ТЬ** *несов.*— 1. (*подвергать пытке*) җәзалау, газаплау; 2. *перен.* йөдәтү, интектерү; җәфалау, азаплау; *не пытайте, расскажите быстрее* — йөдәтмәгез, сөйләгез тизрәк; 3. *обл.* (*испытывать*) сынау; 4. *обл.* (*расспрашивать, разузнавать*) сорашып белү, сорашу; 5. *простореч.* к. пытаться 1. ◇ **Не пытай старого, а пытай бывалого** (*погов.*) — күп яшәгән ни белгән, күпне күргән шул белгән.

**ПЫТА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. маташу, тырышу, тырышып карау; *пытаться оправдаться*— үзен акларга маташу, акланырга тырышу; 2. *страд.* җәзалану, азаплану.

**ПЫ'ТКА** *ж.*— 1. җәза, җәзалау; 2. газап.

**ПЫТЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— кызыксынучанлык, белергә тырышучанлык.

**ПЫТЛИ'ВЫЙ** — кызыксынучан, белергә тырышучан.

**ПЫ'ХАТЬ** *несов. разг.*— 1. бәрү, бәреп тору; *печь пышет жаром* — мичтән эссе бәреп тора; 2. (*лопаться*) шартлау, шартлап ярылу. ◇ **Весь он пышет весельем** — аның йөзендә шатлык балкып тора.

**ПЫХНУ'ТЬ** *сов. разг.*— бәрү; *из печи пыхнуло жаром* — мичтән эссе бәрде.

**ПЫХТЕ'ТЬ** *несов.*— 1. мышнау; авыр сулау; 2. (*о машинах*) уфылдау; 3. *перен.* азаплану; *второй час пыхтит над задачей*— икенче сәгать инде мәсьәлә чишеп азаплана.

**ПЫ'ШКА** *ж. разг.*— 1. кабартма; 2. *перен. фам.* тутырган тавык (түгәрәк йөзле һәм тулы кешегә карата әйтелә).

**ПЫ'ШНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— 1. зиннәтлелек; 2. кабарынкылык, кабарып тору.

**ПЫ'ШНЫЙ** — 1. *книж.* зиннәтле, бик бай *пышный наряд* — бик бай кием; 2. кабарынкы; күперенке, күперен торган; *пышная причёска* — күпереп торган причёска.

**ПЬЕДЕСТА'Л** *м.*— 1. пьедестал, нигез (һәйкәл нигезе); 2. *перен.* авторитет, абруй, пьедестал, (җәмгыятьтә тоткан) югары урын; *низвергнуть с пьедестала* — авторитетын төшерү, пьедесталдан төшерү; *вознести на пьедестал* — авторитетын күтәрү, югары урынга күтәрү, пьедесталга күтәрү.

**ПЬЕ'КСЫ** *ед.* нет, *спорт.*— пьекса (чаңгы шуганда кия торган махсус аяк киеме).

**ПЬЕРО'** *м. нескл.*— мәзәкче, шамакай (итальян халык комедиясе герое Пьеро исеме буенча).

**ПЬЕ'СА** *ж.*— пьеса (1. драматик әсәр; 2. кечкенә музыкаль әсәр; 3. *устар.* кечкенә әдәби әсәр).

**ПЬЮ'ЩИЙ** — эчкече, аракы эчүче, эчә торган кеше.

**ПЬЯНЕ'ТЬ** *несов.*— 1. исерү; 2. *перен.* баш әйләнү, исерү; *пьянеть от радости* — шатлыктан баш әйләнү, шатлыктан исерү.

**ПЬЯНИ'КА** *ж. обл.*— к. голубика.

**ПЬЯНИ'ТЬ** *несов.*— 1. исертү; *вино его быстро пьянит* — вино аны тиз исертә; 2. *перен.* башны әйләндерү, исертү; *его пьянят успехи* — уңышлар аның башын әйләндерәләр.

**ПЬЯ'НИЦА** *м.* и *ж. разг.*— эчкече, исерекбаш.

**ПЬЯ'НКА** *ж. простореч.* — 1. эчү мәҗлесе; 2. к. пьянство.

**ПЬЯ'НСТВО** *ср. мн.* нет — эчкечелек, эчкечелеккә бирелү.

**ПЬЯ'НСТВОВАТЬ** *несов.*— эчү, эчүгә бирелү.

**ПЬЯНЧУ'ГА** *м.* и *ж. простореч. неодобр.*—к. пьяница.

**ПЬЯ'НЫЙ** — 1. (*нетрезвый*) исерек, исергән, эчкән; 2. *в знач. сущ.* эчкән кеше, исерек; 3. тиз исертә торган; *пьяное вино* — тиз исертә торган вино; 4. *перен.* исергән, башы әйләнгән. ◇ **По пьяной лавочке** *вульг.*, **с пьяных глаз** *разг.*— исерек баштан. **Пьяный хлеб** *спец.*—исерткеч икмәк, агулы икмәк (үзенә бертөрле гөмбә авырулы бөртекле ашлык яки шуның оныннан пешерелгән икмәк).

**ПЭР** *м. полит.*— пэр (Франциядә һәм Англиядә дворяннар титулы).

**ПЭ'РСТВО** *ср. мн.* нет, *полит.*— пэрлык, пэр званиесе.

**ПЮПИ'ТР** *м.*— пюпитр (нота кую өчен хезмәт итә торган җайланма).

**ПЮРЕ'** *ср. нескл.* — пюре, измә, ботка; *картофельное пюре* — бәрәңге боткасы.

**ПЯДЕ'НИЦА** *ж. зоол.*— карышлавык (корткыч күбәләк).

**ПЯДЕ'НЬ** *ж. старин.*— к. пядь.

**ПЯДЬ** *ж.*— карыш, сөям (озынлык). ◇**Семи пядей во лбу** *разг.*— бик акыллы.

**ПЯ'ЛИТЬ** *несов. спец.*— киерү. ◇**Пялить глаза** *простореч. фам. чаще неодобр.* — күзләрне акайту.

**ПЯ'ЛИТЬСЯ** *несов.*— 1. *простореч. фам.* сузылу; *пялиться из окна* — тәрәзәдән сузылу; 2. *страд. спец.* киерелү.

**ПЯ'ЛО** *ср. спец. обл.*— киерге, киергеч.

**ПЯ'ЛЬЦЫ** *ед.* нет — киерге (чигү чиккәндә кулланыла торган җайланма).

**ПЯ'СТНЫЙ: пястные кости** — уч сөякләре.

**ПЯСТЬ** *ж.*— уч сөякләре.

**ПЯТА'** *ж.*— 1. *книж. ритор. устар.* к. пятка; 2. *тех.* табан, нигез. ◇**По пятам (ходить)** — эзеннән (йөрү), артыннан бер дә калмыйча (йөрү). **Под пятой** *книж. ритор.*—изүе астында, табаны астында. **Ахиллесова пята** — к. Ахиллес. **С (или от) головы до пят** *разг.*—баштанаяк, башыннан аягына кадәр.

**ПЯТА'К** *м. простореч.*— 1. (*сумма*) биш тиен; 2. (*монета*) биш тиенлек акча.

**ПЯТАКО'ВЫЙ** *разг.*— к. пятачковый.

**ПЯТАЧКО'ВЫЙ** *простореч.*— биш тиенлек.

**ПЯТАЧО'К** *м. разг.*— 1. к. пятак; 2. *обл.* (дуңгызның) борын очы.

**ПЯТЕРИ'К** *м.*— 1. биш потлы кап; 2. *обл.* биш ат җигүле арба; 3. *обл.* биш бармак.

**ПЯТЕРИКО'ВЫЙ** *спец. обл.*— биш потлы; *пятериковый куль* — биш потлы кап. ◇**Пятериковая свеча** — биш шәм.

**ПЯТЁРКА** *ж. разг.*— 1. (*цифра*) бишлек; 2. бишенче, бишенче номерлы трамвай (троллейбус, автобус һ. б.); 3. (*школьная отметка*) бишле билгесе; 4. (*денежный знак*) бишлек, биш сумлык акча; 5. (*группа из пяти человек*) биш (кеше); 6. *разг.* к. пятерик 2.

**ПЯТЕРНО'Й** *разг.*— 1. биш мәртәбә артык, биш тапкыр артык, биш тапкыр күбрәк; *пятерное количество денег* — биш тапкыр артык акча; 2. *спец.* биш кисәктән тора торган, биш кисәктән гыйбарәт, биш кисәкле.

**ПЯТЕРНЯ'** *ж. разг. фам.*— биш бармак (биш бармагы да җәелгән кул).

**ПЯ'ТЕРО** — бишәү, бишәүләп.

**ПЯТЁРОЧНИК** *м.*, **ПЯТЁРОЧНИЦА** *ж. школьн.*— бишлегә генә укучы, отличник.

**ПЯТИАЛТЫ'ННЫЙ** *м. разг. фам.*— унбиш тиенлек акча, унбиш тиен акча.

**ПЯТИБО'РЬЕ** *ср. мн.* нет, *спорт.*— бишле ярыш (спорт ярышының бер төре).

**ПЯТИВЁРСТКА** *ж. спец.*— пятивёрстка (бер дюймы биш чакрымны белдерә торган географик карта).

**ПЯТИГЛА'ВЫЙ** *книж.*— 1. биш башлы; 2. биш гөмбәзле; *пятиглавый собор* — биш гөмбәзле собор.

**ПЯТИГРА'ННИК** *м. мат.* — бишкырлык, биш кырлы геометрик җисем.

**ПЯТИГРА'ННЫЙ** *мат.*— биш кырлы.

**ПЯТИДЕСЯТИЛЕ'ТИЕ** *ср.*— 1. илле ел; *прослужил целое пятидесятилетие* — илле ел буе хезмәт итте; 2. (*годовщина*) илле еллык.

**ПЯТИДЕСЯТИЛЕ'ТНИЙ** —1. илле еллык; *пятидесятилетний срок* — илле еллык срок; 2. илле яшьлек; *пятидесятилетний мужчина* — илле яшьлек ир кеше.

**ПЯТИДЕСЯ'ТНИК** *м. публиц.*— пятидесятник (XIX гасырның 50 нче елларында Россиядә җәмәгать эшлеклесе, интеллигент).

**ПЯТИДЕСЯ'ТЫЙ** — илленче.

**ПЯТИДНЕ'ВНЫЙ** — биш көнлек; *пятидневный срок* — биш көнлек срок.

**ПЯТИКЛА'ССНИК** *м.*, **ПЯТИКЛА'ССНИЦА** *ж.*— бишенче класс укучысы.

**ПЯТИКЛА'ССНЫЙ** — 1. биш класслы; *пятиклассная школа* — биш класслы мәктәп; 2. биш класслык; *пятиклассное образование* — биш класслык белем.

**ПЯТИКОНЕ'ЧНЫЙ** — биш почмаклы; *пятиконечная звезда* — биш почмаклы йолдыз.

**ПЯТИКОПЕ'ЕЧНЫЙ** — биш тиенлек.

**ПЯТИКРА'ТНЫЙ** *книж.*— 1. биш тапкыр, биш тапкыр кабатланган; *пятикратное посещение* — биш тапкыр килү (бару); 2. (*увеличенный в пять раз*) бишләтә, биш тапкыр арттырылган (кабатланган). ◇**В пятикратном размере** — бишләтә арттырып.

**ПЯТИЛЕ'ТИЕ** *ср. книж.*— 1. биш ел; 2. биш еллык.

**ПЯТИЛЕ'ТКА** *ж.*—1. бишьеллык; *первая пятилетка* — беренче бишьеллык; 2. (*пятилетний план*) бишьеллык план; 3. биш яшьлек; *девочка-пятилетка* — биш яшьлек кыз.

**ПЯТИЛЕ'ТНИЙ** — 1. бишьеллык; *пятилетний срок* — бишьеллык срок; 2. биш яшьлек; *пятилетний ребёнок* — биш яшьлек бала

**ПЯТИМЕ'СЯЧНЫЙ** — биш айлык.

**ПЯТИ'НА** *ж. истор.*— пятина (борынгы Русьта Бөек Новгородның җирләре биш административ районга бүленгән; аларның һәрберсе „пятина" дип аталган).

**ПЯТИПА'ЛЫЙ** — биш бармаклы.

**ПЯТИРУБЛЁВКА** *ж. разг.*— биш сумлык (акча).

**ПЯТИРУБЛЁВЫЙ** — биш сумлык.

**ПЯТИСЛО'ЖНЫЙ** *грам.*— биш иҗекле.

**ПЯТИСЛО'ЙНЫЙ** — биш катлы.

**ПЯТИСО'ТЕННЫЙ** *разг.*— биш йөзлек, биш йөз сумлык; *пятисотенный костюм* — биш йөз сумлык костюм.

**ПЯТИСО'ТКА** *ж.* — 1. *простореч.* биш йөзлек, биш йөз сумлык акча; 2. *разг. спорт.* биш йөз метр ара.

**ПЯТИСОТЛЕ'ТИЕ** *ср.*— 1. биш йөз ел; 2. (*годовщина*) биш йөз еллык.

**ПЯТИСО'ТНИЦА** *ж.*— биш йөзче (алдынгы колхозчы хатын-кыз турында; башта — гектарыннан 500 центнер чөгендер уңышы алган колхозчы хатын-кыз турында).

**ПЯТИСО'ТЫЙ** — биш йөзенче.

**ПЯТИСТЕ'ННИК** *м.*— алты почмаклы өй.

**ПЯТИСТИ'ШИЕ** *лит.*— биш юллы шигырь, биш юллы строфа.

**ПЯТИСТО'ПНЫЙ** *лит.*— биш буынлы, биш стопалы.

**ПЯТИТО'НКА** *ж.*— биш тонналы машина.

**ПЯТИТО'ННЫЙ** — биш тонналы.

**ПЯТИТЫ'СЯЧНЫЙ** — 1. биш меңенче; 2. биш меңле; ***пятитысячный отряд***— биш меңле отряд.

**ПЯ'ТИТЬ** *несов.*— чигендерү, артка чигерү.

**ПЯ'ТИТЬСЯ** *несов.*— чигенү, артка чигү.

**ПЯТИУГО'ЛЬНИК** *м. мат.*— бишпочмак.

**ПЯТИУГО'ЛЬНЫЙ** — бишпочмаклы.

**ПЯТИ'ШНИЦА** *ж. простореч. фам.*— к. пятирублёвка.

**ПЯТИЭТА'ЖНЫЙ** — биш катлы.

**ПЯ'ТКА** *ж.* — үкчә. ◇ **Душа в пятки ушла** — к. душа. **Только пятки сверкают** *разг.*— үкчәләре генә ялтырый (тиз йөгерү турында). **Показать пятки** *разг.*— үкчә ялтырату. **От головы до пяток** — баштанаяк, башыннан аягына кадәр.

**ПЯТНАДЦАТИЛЕ'ТИЕ** *ср.*— 1. унбиш ел; 2. *(годовщина)* унбиш еллык.

**ПЯТНАДЦАТИЛЕ'ТНИЙ** — 1. унбиш еллык; ***пятнадцатилетний срок***— унбиш еллык срок; 2. унбиш яшьлек; ***пятнадцатилетний мальчик***— унбиш яшьлек малай.

**ПЯТНА'ДЦАТЫЙ** — унбишенче.

**ПЯТНА'ДЦАТЬ** — унбиш.

**ПЯТНА'ТЬ** *несов.*— 1. *(пачкать пятнами)* тапландыру, таплар төшерү; 2. *перен. книж.* *(позорить)* хур итү, тап төшерү, яман атын сату; 3. *разг.* *(при игре в пятнашки)* әбәкләү.

**ПЯТНА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. таплану; тап төшерелү; 2. *перен.* хур ителү, тап төшерелү.

**ПЯТНА'ШКИ** *ед.* нет, *разг.*— әбәкләшү уены (балалар уены).

**ПЯТНИ'СТЫЙ** — ала-кола, тимгелле.

**ПЯТНИ'ТЬ** *несов. просторечь.*— к. пятнать 1.

**ПЯ'ТНИЦА** *ж.* — жомга. ◇ **Семь пятниц на неделе** — һавасы көн дә алышына (сүзендә, вәгъдәсендә тормаучан кеше турында әйтелә).

**ПЯ'ТНИЧНЫЙ** *разг.*— жомга көнне була торган.

**ПЯТНО'** *ср.*— тап. ◇ **И на солнце есть пятна** — кояшта да таплар бар (һәркемнең дә житешсез ягы була).

**ПЯТО'К** *м.*— 1. *разг.* биш; ***пяток яблок***— биш алма; 2. *разг. школьн. устар.* бишлек билгесе; 3. *устар.* к. пятница.

**ПЯ'ТОЧНЫЙ** — үкчә...-ы; ***пяточное сухожилие***— үкчә сенере.

**ПЯ'ТЫЙ** — бишенче. ◇ **Из пятого в десятое** — к. десятый.

**ПЯТЬ** — биш.

**ПЯТЬДЕСЯ'Т** — илле.

**ПЯТЬСО'Т** — биш йөз.

**ПЯ'ТЬЮ** *нареч.*— биш тапкыр, биш жирдә; ***пятью пять — двадцать пять***— биш жирдә бишең егерме биш.

# Р

**РАБ** *м.*— 1. кол; ***восстание рабов***— коллар восстаниесе; 2. кол крестьян, крепостной игенче; ***поля, возделанные рабами***— кол крестьяннар эшкәрткән басулар; 3. *перен. ритор. презрит.* кол, (сукыр рәвештә) тез чүгүче, баш июче, тәлинкә тотучы, ялагай. ◇ **Раб божий** *устар. шутл.*— алла колы, хода бәндәсе, мәхлук.

**РАБА'** *ж.* (*мн.* рабыни) — 1. кол (хатынкыз); 2. жәрия, кәнизәк.

**РАБА'ТКА** *ж. сад.*— чәчәк түтәле (стена, сукмак буйларына ясалып, чәчәк утыртылган тар, озын түтәл).

**РА'БИЙ** *устар.*— 1. кол...-ы; коллар...-ы; ***рабья одежда***— коллар киеме; 2. *перен. презрит. ритор.* колларча..., колларга хас; коллык...-ы, ялагайлык...-ы; ***рабье послушание***— колларча буйсыну; ***рабьи привычки***— ялагайлык гадәтләре.

**РАБКО'Р** (рабочий корреспондент) *м.*— рабкор, эшче хәбәрче; ***рабкоры пишут***— эшче хәбәрчеләр язалар.

**РАБКО'РОВСКИЙ** — эшче хәбәрчеләр...-ы, рабкорлар...-ы; ***рабкоровские письма***— эшче хәбәрчеләрнең хатлары; ***рабкоровское движение***— рабкорлар хәрәкәте.

**РАБОВЛАДЕ'ЛЕЦ** *м.*, **РАБОВЛАДЕ'ЛИЦА** *ж.*— кол биләүче; кол иясе, кол хужасы.

**РАБОВЛАДЕ'ЛЬЧЕСКИЙ** *книж.*— колбиләүчелек...-ы; коллыкка нигезләнгән, коллык...-ы; ***рабовладельческое общество***— колбиләүчелек җәмгыяте; ***рабовладельческое хозяйство***— коллыкка нигезләнгән хужалык.

**РАБОВЛАДЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— кол биләү, колбиләүчелек, кол биләүчелек строе.

**РАБОЛЕ'ПИЕ** *ср. мн.* нет, *книж. презрит. устар.*— к. раболепство.

**РАБОЛЕ'ПНО** *нареч.*— колларча, колларча баш иеп; ялагайланып, ярарга тырышып; ***раболепно вести себя***— үзен колларча тоту.

**РАБОЛЕ'ПНЫЙ** *книж. презрит.*— колларча баш иеп..., тәлинкә тотып..., ялагайланып...; ***раболепная просьба***— ялагайланып сорау, колларча баш иеп үтенү.

**РАБОЛЕ'ПСТВО** *ср. мн.* нет, *книж. презрит.*— колларча баш ию, ярарга тырышу(чанлык); ялагайлык, тәлинкә тоту; тез чүгү.

**РАБОЛЕ'ПСТВОВАТЬ** *несов. книж. презрит.*— колларча баш ию; ярарга тырышып баш ию; ялагайлану, тәлинкә тоту, тез чүгү; ***правые социалисты раболепствуют перед буржуазией***— уң социалистлар буржуазия алдында тез чүгәләр.

**РАБО'ТА** *ж.* — 1. к. работать; *бес-*

*перебойная работа машины* — машинаның тоткарсыз эшләве; **2.** эш, хезмәт; *физическая работа* — физик эш, физик хезмәт; *умственная работа* — акыл хезмәте; *научная работа* — фәнни эш; *у него много печатных работ* — аның басылып чыккан хезмәтләре (әсәрләре) күп. ◇ **Не годится в работу** — эшкәртергә ярамый, эшкә яраксыз (әйбер ясап булмый). **Поденная работа** — көнлекле эш. **Сдельная работа** — эш башыннан эшләү. **Работа спорится** — эш уңышлы бара. **Адская работа** — бик читен эш, авыр эш. **Взять в работу** — к. оборот. **Сизифова работа (труд)** — Сизиф эше (бетмәс-төкәнмәс файдасыз эш). **Домашняя работа** *школьн.* — өйгә эш, бирем. **Единица работы** *физ.* — эш берәмлеге. **Гостить с работой** — утырмага бару, утырмада утыру.

**РАБО'ТАТЬ** *несов.* — **1.** эшләү; *работать в колхозе* — колхозда эшләү; **2.** эшләү, шөгыльләнү; *работать над древними рукописями* — борынгы кулъязмалар өстендә эшләү; **3.** эш итү; *работать с книгой* — китап белән эш итү; **4.** кулланып эшләү, файдаланып эшләү; *работать со словарем* — сүзлек кулланып эшләү; **5.** тәҗрибә ясау; *работать на кроликах* — йорт куяннарына тәҗрибә ясау; **6.** хезмәт кую; хезмәт итү; *работать для науки* — фән өчен хезмәт итү; **7.** *простореч. спец.* ясау, җитештерү, эшләп чыгару; *работать шкатулки* — шкатулкалар ясау. ◇ **Работать лошадь** *спец.* — атны өйрәтү (атланып, җигеп йөрергә). **Работать над собой** — үз өстендә эшләү (белемеңне арттыру). **Работать локтями** — этешү-төртешү; *выбрался из толпы, работая локтями* — этешә-төртешә халык төркемен ерып чыкты.

**РАБО'ТАТЬСЯ** *несов. безл. разг.* — эш бару, эшләнү; *сегодня хорошо работается* — бүген яхшы эшләнә, бүген эш яхшы бара.

**РАБО'ТНИК** *м.* — **1.** эшләүче, хезмәт итүче; *боровой работник* — бушка эшләүче; **2.** работник, эшче; *работники печати* — матбугат эшчеләре; *инженерно-технические работники* — инженер-техник работниклар; **3.** *устар.* ялчы, хезмәтче; *хозяин и работник* — хуҗа һәм хезмәтче; **4.** *устар.* (*рабочий*) эшче.

**РАБО'ТНИЦА** *ж.* — **1.** к. работник 1, 3; **2.** эшче хатын-кыз; *работницы текстильной промышленности* — текстиль промышленностеның эшче хатын-кызлары. ◇ **Домашняя работница** — асрау (хезмәтче хатын-кыз).

**РАБО'ТНИЦКИЙ** *устар.* — эшче...-ы; *работницкая одежда* — эшче киеме.

**РАБО'ТНИЧИЙ** *устар.* — к. работницкий.

**РАБО'ТНЫЙ** *устар.* — эш...-ы; *работные дни* — эш көннәре.

**РАБОТОДА'ТЕЛЬ** *м. экон.* — **1.** эш бирүче, эш эшләтүче, яллаучы; **2.** предприниматель.

**РАБОТОРГО'ВЕЦ** *м.* — коллар сәүдәгәре; коллар белән сату итүче, коллар белән сәүдә итүче.

**РАБОТОРГО'ВЛЯ** *ж. мн.* нет — кол сәүдәсе, коллар белән сәүдә итү (сату итү); *в колониях процветала работорговля* — колонияләрдә коллар белән сәүдә итү бик киң таралган иде.

**РАБОТОСПОСО'БНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — эшкә сәләтлелек, эшкә яраклылык.

**РАБОТОСПОСО'БНЫЙ** *книж.* — **1.** эшкә сәләтле, эшкә яраклы; *работоспособный человек* — эшкә сәләтле кеше; **2.** күп эшләүче; эшчән; *работоспособный учёный* — эшчән галим.

**РАБОТЯ'ГА** *м.* и *ж. разг. фам.* — эшчән кеше, эшкә батыр (эшкә таза) кеше.

**РАБОТЯ'ЩИЙ** *простореч.* — эшчән, тырыш, эш сөючән; *он парень работящий* — ул эшчән егет.

**РАБО'ЧАЯ** *ж. простореч.* — эшче хатын-кыз.

**РАБОЧЕДЕ'ЛЕЦ** *м. полит. истор.* — рабочеделец, рабочеделочы, „Рабочее дело" тарафдары („Рабочее дело" журналы тоткан юнәлешне — XX йөз башында рус социал-демократиясе хәрәкәтендә экономизмның бер төре булган оппортунистик агымны — яклаучы).

**РАБО'ЧЕ-КРЕСТЬЯ'НСКИЙ** *нов.* — эшче-крестьян(нар)...-ы; *рабоче-крестьянское правительство* — эшче-крестьян хөкүмәте.

**РАБО'ЧИЙ** I *м.* — эшче; *рабочие фабрик и заводов* — фабрика һәм завод эшчеләре.

**РАБО'ЧИЙ** II — **1.** эшче...; *рабочая молодежь* — эшче яшьләр; **2.** эшчеләр...ы; *рабочий класс* — эшчеләр сыйныфы; **3.** эш...-ы; *рабочее время* — эш вакыты, эш өсте; **4.** *разг.* хезмәт...-ы; хезмәтчән; *рабочий народ* — хезмәт халкы, хезмәтчән халык; **5.** *разг.* к. работящий; **6** *тех.* эш башкаручы, хәрәкәткә китерүче; *рабочие части машины* — машинаның эш башкаручы частьлары. ◇ **Рабочий костюм** — эш костюмы (эшкә кия торган кием). **Рабочий экземпляр** — эшкә дигән нөсхә. **Рабочий период** — эшкә киткән вакыт (период). **Рабочая лошадь** — эш аты, йөк аты. **Рабочая пчёлка** — эшче корт. **Рабочая гипотеза** — ярдәмче гипотеза (гыйльми эш барышында шартлы рәвештә алынган вакытлы ярдәмче гипотеза). **Рабочий люд** — эшчеләр. **Рабочие руки** — эшче көчләр, эш куллары, эшчеләр. **Рабочая сила** — **1.** *экон.* эш көче; **2.** эшчеләр. **Рабочий чертёж** — кулланма сызым (эшне башкарганда турыдан-туры кулланыла торган сызым).

**РАБСЕЛЬКО'РЫ** (рабочие и сельские корреспонденты) *мн.* — эшче-крестьян хәбәрчеләре.

**РА'БСКИ** *нареч.* — колларча, колдай, кол кебек; *рабски подражать* — колларча ияру.

**РА'БСКИЙ** — **1.** коллык...-ы; кол(лар)...-ы; *рабский труд* — кол хезмәте; *рабское положение* — коллык хәле; **2.** *перен. книж. пренебр.* колларча...; сукыр рәвештә; *рабская покорность* — колларча күндәмлек; **3.** *перен. книж. презрит.* ялагай, сатлык; *рабская душонка* — сатлык җан.

**РА'БСТВО** *ср. мн.* нет — **1.** коллык,

коллык хәле, кол булу; *освободиться от рабства* — коллыктан котылу; 2. *экон.* коллык җәмгыяте, коллык строе; *при рабстве* — коллык җәмгыятендә; 3. *перен.* коллык, изү, изелү; *освободиться от капиталистического рабства* — капитализм коллыгыннан котылу; 4. *перен.* колларча буйсыну, бирелү, кол булу.

**РА'БСТВОВАТЬ** *несов. устар.* — к. раболепствовать.

**РАБФА'К** (рабочий факультет) *м.* — рабфак (эшчеләр факультеты).

**РАБЫ'НЯ** *ж.* — к. раба.

**РАВВИ'Н** *м.* — раввин (еврей рухание).

**РАВВИНА'Т** *м. мн.* нет, *собир. спец.* — раввинат, раввиннар мәхкәмәсе.

**РАВЕЛИ'Н** *м. воен. устар.* — равелин (борынгы крепостьларда стенаның тышкы ягына чыгарып эшләнгән өстәмә ныгытма).

**РАВЕНДУ'К** *м. спец.* — равендук, калын киндер, җилкәнлек киндер.

**РА'ВЕНСТВО** *ср. книж.* — 1. тигезлек, бәрабәрлек, тиңлек, бердәйлек; бертигез (тиң, бәрабәр) булу; *равенство сил* — көчләрнең бертигез булуы, бәрабәр булуы; 2. тигез хокуклылык, тигез дәрәҗәлелек; 3. *мат.* тигезлек; *знак равенства* — тигезлек билгесе.

**РАВНЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. *воен.* тигезләү, тигезләнү; *равнение направо* — уңга карап тигезләнү; 2. тиңләшү; *равнение на передовых* — алдынгылар белән тиңләшү, алдынгыларга тиңләшү.

**РАВНЁХОНЬКИЙ** *простореч.* — тип-тигез, төп-төгәл генә, җитәрлек кенә.

**РАВНИ'НА** *ж.* — тигезлек, тигез җир.

**РАВНИ'ННЫЙ** *геогр.* — тигезлек..-ы, тигез җир...-ы; *равнинный ландшафт* — тигезлек ландшафты (тигез җир күренеше).

**РАВНО'** — 1. *нареч.* барыбер, бердәй, бер үк; *равно красивы горы и леса* — таулары да, урманнары да бердәй матур; 2. *мат. в знач. сказ.* тигез, (тигез) була. ◇ **Равно как или равно и или а равно** *книж.* — кебек үк, шикелле үк; *фруктовые деревья, равно и прочие культурные растения, требуют ухода* — җимеш агачлары, башка культуралы үсемлекләр кебек үк, тәрбия таләп итәләр. **Всё равно** — барыбер.

**РАВНОБЕ'ДРЕННИК** *м. мат. разг.* — тигезьянлы өчпочмак.

**РАВНОБЕ'ДРЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *мат.* — тигезьянлылык.

**РАВНОБЕ'ДРЕННЫЙ** *мат.* — тигезьянлы; *равнобедренный треугольник* — тигезьянлы өчпочмак.

**РАВНОВЕЛИ'КИЙ** *книж. науч.* — тигез (бердәй) зурлыктагы, бертигез; *равновеликие фигуры* — тигез зурлыктагы фигуралар.

**РАВНОВЕ'СИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — 1. тигезлек; тигезләнү, тигезләнеш; *равновесие сил* — көчләрнең тигезлеге (тигезлек хәле); *устойчивое равновесие* — тотрыклы тигезләнеш; 2. тигезлек саклау; *теория „равновесия"* — „тигезлек саклау" теориясе; 3. *перен. книж.* тотрыклылык; *политическое равновесие* — политик тотрыклылык; 4. *перен.* тынычлык; *душевное равновесие* — күңел тынычлыгы. ◇ **Вывести кого-н. из равновесия** — ... чыгырыннан чыгару, ачуын кузгату.

**РАВНОВЕ'СНЫЙ** *физ.* — тигезлек (тигезләнү, тигезләнеш)...-ы; *равновесное положение тела* — җисемнең тигезлек хәле.

**РАВНОВЕСО'МЫЙ** *книж. спец.* — тигез авырлыктагы, авырлыгы тигез (тиң, бәрабәр) булган; *предметы равновесомые* — авырлыклары тигез (тиң, бәрабәр) булган әйберләр.

**РАВНОДЕ'ЙСТВУЮЩАЯ** *ж. в знач. сущ. мех.* — бердәй тәэсир итүче (көч).

**РАВНОДЕ'ЙСТВУЮЩИЙ** *книж.* — бердәй (бертигез) тәэсир итүче; *равнодействующие силы* — бердәй тәэсир итүче көчләр.

**РАВНОДЕ'НСТВИЕ** *ср. астр.* — көн-төн тигезлеге (көн һәм төн бертигез 12 шәр сәгать булган вакыт); *весеннее равноденствие* (21 марта) — язгы көн-төн тигезлеге; *осеннее равноденствие* (23 сентября) — көзге көн-төн тигезлеге.

**РАВНОДУ'ШИЕ** *ср. мн.* нет — салкын (сүлпән) карау, игътибарсызлык, илтифатсызлык, ваемсызлык, тыныч күңеллелек; *бюрократическое равнодушие* — бюрократларча салкын карау.

**РАВНОДУ'ШНО** *нареч.* — игътибарсыз (илтифатсыз) рәвештә; кызыксынмыйча, искитмичә, күңел бирмичә; *равнодушно смотреть* — искитмичә карау.

**РАВНОДУ'ШНЫЙ** — 1. кызыксынмаучан, игътибарсыз, илтифатсыз, ваемсыз; *равнодушный человек* — ваемсыз кеше; 2. *(холодно-спокойный)* салкын, сүлпән; дәртсез; 3. *разг. фам. в знач. сказ.* кызыксынмый, яратмый, (һ)әвәс түгел; *он совершенно равнодушен к шахматам* — ул шахмат белән бөтенләй кызыксынмый.

**РАВНОЗНА'ЧАЩИЙ** *книж.* — бертигез әһәмиятле, бердәй мөһим, бер үк төрле; *равнозначащие явления* — бертигез әһәмиятле күренешләр, бер үк төрле күренешләр.

**РАВНОЗНА'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — тигез кыйммәтлелек; тигез мәгънәлелек.

**РАВНОЗНА'ЧНЫЙ** *книж.* — 1. *мат.* тигез кыйммәтле; *равнозначные величины* — тигез кыйммәтле зурлыклар; 2. *лингв.* мәгънәдәш, бер мәгънәдәге, тигез мәгънәле; *равнозначные слова называются синонимами* — мәгънәдәш сүзләр синонимнар дип атала.

**РАВНОМЕ'РНО** *книж.* — 1. *нареч.* тигез итеп, бертигез итеп; бертөрле; *равномерно распределить обязанности* — эшләрне тигез итеп бүлү; 2. *устар. в знач. союза* шулай ук, беррәттән; *во все губернские, равномерно и в уездные города были разосланы циркуляры* — барлык губерна һәм шулай ук өяз шәһәрләренә циркулярлар җибәрелде.

**РАВНОМЕ'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — бертигезлек, бертөрлелек.

**РАВНОМЕ'РНЫЙ** *книж.* — 1. *устар.* тигез үлчәүле, тигез үлчәнешле; *равномерные*

*величины* — тигез үлчәнешле зурлыклар; 2. бертөрле, тигез; *равномерная скорость* — бертөрле тизлек; *равномерное развитие* — тигез үсеш; 3. *перен.* салмак, тигез; *равномерная поступь* — салмак адым.

**РАВНОПЛЕ'ЧИЙ** *физ. тех.* — тигез инсәле; *равноплечий рычаг* — тигез инсәле рычаг.

**РАВНОПРА'ВИЕ** *ср. мн.* нет — 1. тигез хокуклылык, хокукта тигезлек; *равноправие граждан СССР* — СССР гражданнарының тигез хокуклылыгы; 2. *перен.* бертигез кыйммәткә (әһәмияткә) ия булу.

**РАВНОПРА'ВНЫЙ** — 1. тигез хокуклы; *равноправный гражданин* — тигез хокуклы граждан; 2. *перен.* тиң кыйммәтле, бердәй әһәмиятле, бертигез кыйммәткә ия булган.

**РАВНОСИ'ЛЬНЫЙ** *книж.* — 1. тигез көчле, тиң көчле; көчләре тиң булган, бертигез булган; *равносильные борцы* — көчләре бертигез булган көрәшчеләр; 2. бердәй (бер үк, шундый ук) көчкә ия булган; *равносильные доводы* — бердәй көчкә ия булган дәлилләр; 3. *в знач. сказ.* белән бер, ... белән бәрабәр; *ваше утверждение равносильно отрицанию* — сезнең раславыгыз инкарь итү белән бер.

**РАВНОСТОРО'ННИЙ** *мат.* — тигезьяклы; *равносторонний треугольник* — тигезьяклы өчпочмак.

**РАВНОУГО'ЛЬНИК** *м. мат. разг.* — тигезпочмаклык, тигезпочмаклы геометрик фигура (күппочмак һ. б.).

**РАВНОУГО'ЛЬНЫЙ** *мат.* — тигезпочмаклы; *равноугольный многоугольник* — тигезпочмаклы күппочмак.

**РАВНОУСКО'РЕННЫЙ** *физ.* — тигез тизләнешле; *равноускоренное движение* — тигез тизләнешле хәрәкәт.

**РАВНОЦЕ'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет — тигез бәялелек; бердәй әһәмиятлелек, бер үк әһәмияткә ия булу; тигез кыйммәтле, тигез сыйфатлы булу.

**РАВНОЦЕ'ННЫЙ** — 1. бертигез бәяле, бер үк бәяле, бердәй бәяле; *равноценные товары* — бер үк бәяле товарлар; 2. *перен.* тигез сыйфатлы, тиң сыйфатлы; тигез кыйммәтле; *равноценные работники* — тиң сыйфатлы работниклар.

**РА'ВНЫЙ** — 1. тигез, бертигез; бер үк, бердәй, бәрабәр; *равные силы* — тигез көчләр, бәрабәр көчләр; *брёвна равной толщины* — бер үк юанлыктагы бүрәнәләр; 2. *в знач. сущ.* тиң, иш; бер дәрәҗәдәге кеше; *говорил как с равным* — үз тиңе белән сөйләшкәндәй сөйләште. ◇ **Не считать равным** — тиң күрмәү, тиңсенмәү. **При прочих равных условиях** — башка шундый ук шартларда, башка шартлары да шундый ук булганда. **Равным образом** — шулай ук. **Не имеющий себе равных (в истории)** — тиңдәше булмаган, тиңдәшсез, тиңсез (тарихта күрелмәгән, мисалы булмаган).

**РАВНЯ'ТЬ** *несов.* — 1. тигезләү; *равнять ряды* — сафларны тигезләү; *смерть всех равняет (погов.)* — үлем һәркемне тигезли (үлгәч аерма калмый); 2. тигез карау, тигез күрү; *мать равняет всех детей* — ана балаларын тигез күрә (барысына да бертигез карый); 3. *разг.* тиңләштерү, тиңләү, тиң күрү; *равнять с собой* — үзең белән тиңләштерү, тиң күрү.

**РАВНЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. тигезләнү, тигезләшү; *равняться по правофланговому* — уң флангтагы кешегә карап тигезләнергә; 2. тиңләшү, тиң санау, тиң булу; *где тебе равняться с ним!* — кая синең аның белән тиңләшергә! 3. (тигез) булу; *трижды три равняется девяти* — өч җирдә өч тугыз була (тугызга тигез була); 4. тиңләшү, үрнәк алу; *равняться по передовым* — алдынгыларга тиңләшү, алдынгылардан үрнәк алу. ◇ **Для меня это равняется катастрофе** — минем өчен бу һәлакәт белән бер (һәлакәт дигән сүз).

**РАГУ'** *ср. нескл. кулин.* — рагу (туралган ит яки балыктан хәзерләнгән ашамлык).

**РАД** (ра́да, ра́до, *мн.* ра́ды) *в знач. сказ.* — 1. шат (мын, сың, быз); куана (м, сың, быз), сөенә (м, сең, без); *я очень рад* — мин бик шат (мын); *мать рада, что сын вернулся домой* — ана улының өйгә кайтуына куана; 2. риза (разый) булу, әзер тору; теләү; шат; *ты рада быть его рабой* — син аның колы булырга да риза (шат, әзер); 3. шатланып... иде (м, н) дә...; *рад отдохнуть, да некогда* — бик шатланып (рәхәтләнеп) ял итәр идем дә, вакытым юк. ◇ **Рад стараться!** — 1. *воен. устар.* рад стараться! 2. баш өсте, һәрвакыт әзер. **И не рад или сам не рад** *разг.* — үкенеп бетә алмыйм, терсәк җитми; *затеял, а теперь сам не рад* — юк эшкә керештем, ә хәзер үкенеп бетә алмыйм. **Хоть рад, хоть не рад или рад не рад** *разг.* — теләсәң дә теләмәсәң дә. **Рад-радёхонек или рад-радёшенек** — бик шат, бик риза; куанычы эченә сыймый.

**РА'ДА** *ж.* — 1. *обл.* ярдәм, киңәш; *подать раду* — киңәш бирү; ярдәм итү; 2. рада (а. *истор.* Украинада — халык җыелышы, киңәшмә, халык җыены; б. Украинада хезмәт ияләре депутатлары советы; в. *истор.* 1917—19 елларда Украина һәм Белоруссиядә — контрреволюцион милләтче оешмаларның үзәк органнары).

**РАДА'Р** *м. спец.* — радар (радиолокация җайланмасы).

**РАДА'РНЫЙ** — радар...-ы; *радарная установка* — радар җайланмасы.

**РАДЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед.* тырышу, кайгырту, иҗтиһат итү; кайгыртып, көенеп йөрү; ярдәмләшү, булышу; *нет у него радения* — ул эш өчен кайгырмый (тырышмый, көйми); 2. *рел.* радение йоласы (кайбер сектантларда үз-үзен кыйнаудан, җырлаудан, биюдән һ. б. гыйбарәт булган дини йола)

**РАДЕ'ТЕЛЬ** *м. устар.* 1. — *(благодетель)* игелекче, игелек күрсәтүче, яхшылык итүче; *(покровитель)* яклаучы, химаяче, канат астына алучы; 2. тырышучы кеше, кайгыртучы (булышучы) кеше; эш өчен көюче.

**РАДЕ'ТЕЛЬНЫЙ** *устар.* — кайгыртучан, тырыш, иҗтиһатлы.

**РАДЕ'ТЬ** *несов.*—1. *устар.* иҗтиһат итү, тырышу, яхшылык итәргә тырышу; кайгырту,... өчен яну (көю); булышу, ярдәм итү; ***радеть друзьям*** — дусларга яхшылык итәргә тырышу; ***радеть о деле*** — эш өчен тырышу, эш турында кайгырту; 2. *рел.* радение йоласы үткәрү.

**РАДЁХОНЕК, РАДЁШЕНЕК** *нескл. простореч.*— бик шат, бик разый, бик те әп риза; ***он радёшенек этому*** — ул моңа бик шат.

**РА'ДЖА** *м.*— раджа (Һиндстанда феодаль князьләргә бирелә торган титул).

**РА'ДИ** *предлог с род. п.*—1. өчен, хакына; хөрмәтенә, йөзеннән; ***ради нашей дружбы*** — дуслыгыбыз хакына; ***ради общего дела*** — гомуми эш өчен; 2. *устар.* хакы өчен; ***ради бога*** — алла хакы өчен; 3. *разг. (в знач. цели)* максаты белән, ...-рга дип, өчен; ***ради отдыха*** — ял итү максаты белән, ял итәргә дип; 4. *разг. (в знач. причины)* сәбәпле, сәбәптән, аркасында, өчен; ***ради чего ему отказываться?*** — ни сәбәпле (ни өчен) аңа баш тартырга? ◇ **Чего ради** *простореч.*— бер-бер сәбәп белән, сәбәп чыгып; ***а чего ради, пожалуй, мне придётся ехать*** — бер-бер сәбәп чыгып, миңа барырга туры килмәгәе. **Ради вас** — сез дигәндә, сезнең өчен, сезгә була.

**РАДИА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *мат. тех.*— радиальлек.

**РАДИА'ЛЬНЫЙ** *мат. тех.*— радиаль (радиус буенча юнәлгән, таралган, төзелгән; нурсыман).

**РАДИА'ТОР** *м. тех.*— радиатор (1. үзәктән ягып җылыту системасында, йортларны җылыту өчен, махсус трубалардан гыйбарәт җайланма; 2. эчке янулы двигательләрдә моторны суыту аппараты).

**РАДИА'ЦИЯ** *ж.*— радиация, нур чәчү (1. *физ.* берәр чыганактан тарала торган нур энергиясе; ***солнечная радиация*** — кояш радиациясе, кояш нур арының таралышы; 2. үзәктән читкә таба нурсыман таралу, җәелү, сибелү).

**РА'ДИЕВЫЙ** — радий...-ы; ***радиевые лучи*** — радий нурлары.

**РА'ДИЙ** *м. хим. физ. мн.* нет — радий (үзеннән-үзе нурлар чыгарып таркала торган химик элемент); ***лечение радием*** — радий белән дәвалау.

**РАДИКА'Л** I *м.*— радикал (1. *полит.* буржуаз дәүләт интересларыннан чыгып, өлешчә демократик реформалар үткәрүне таләп итә торган, сул буржуаз партияләрне яклаучы яки шундый партиянең члены; 2. *перен. устар.* кискен чаралар үткәрү ягында торучы кеше).

**РАДИКА'Л** II *м.*—1. *мат.* радикал, тамыр билгесе (тамыр алу гамәленең тамгасы: $\sqrt{\ }$); 2. *хим.* радикал (химик реакция барышында бер кушылмадан икенчесенә үзгәрешсез күчә торган атомнар төркеме).

**РАДИКАЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет — радикализм (1. радикалларның политик юнәлешләре һәм хәрәкәтләре; 2. *перен.* кискен чаралар үткәрү яки үткәрергә омтылу, кискен хәрәкәт итү).

**РАДИКА'ЛЬНИЧАТЬ** *несов неодобр.*— радикаллану, радикалланган булу, радикал булып кылану; үзен радикалсыман тоту; радикаллык итү.

**РАДИКА'ЛЬНО** *нареч.*— кискен, катгый рәвештә; бөтенләй, тәмам, төбе-тамырыннан, нигезеннән; ***радикально проводить в жизнь*** — катгый рәвештә тормышка ашыру; ***радикально излечиться*** — тәмам (бөтенләйгә) сәламәтләнү; ***радикально изменить*** — тамырыннан үзгәртү.

**РАДИКА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— кискенлек, катгыйлык, радикальлек; ***радикальность мероприятий*** — чараларның катгыйлыгы.

**РАДИКА'ЛЬНЫЙ**—1. *полит.* радикаллар...-ы; радикаллык...-ы; ***радикальная политика*** — радикаллык политикасы; 2. *перен.* кискен, катгый; тамырыннан..., нигезеннән...; ***радикальная мера*** — катгый чара; ***радикальное изменение*** — тамырыннан үзгәртү; 3. радикаль фикерле; ***радикальный человек*** — радикаль фикерле кеше.

**РАДИКУЛИ'Т** *м. мед.*— радикулит, радикулит авыруы (арка миендәге нерв җепселләренең ялкынсынуы сәбәпле бил сызлау).

**РА'ДИО** *ср. нескл.*— радио.

**РАДИОАКТИ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *хим. физ.*— радиоактивлык (кайбер химик элементларда атом төшенең күзгә күренми торган нур чыгарып үзлегеннән таркалуы); ***искусственная радиоактивность*** — ясалма радиоактивлык.

**РАДИОАКТИ'ВНЫЙ** *хим. физ.*— радиоактив, радиоактивлы, радиоактивлык...-ы; радиоактивлык сыйфаты булган; ***радиоактивные явления*** — радиоактивлык күренешләре; ***радиоактивные элементы*** — радиоактив элементлар (радий, уран һ. б.).

**РАДИОАППАРА'Т** *м. тех.*— радиоаппарат, радио аппараты (радио дулкыннарын кабул итү яки тапшыру аппараты).

**РАДИОАППАРАТУ'РА** *ж. мн.* нет — радиоаппаратлар, радио аппаратлары, радио җиһазлары.

**РАДИОВЕЩА'НИЕ** *ср. мн.* нет—1. радиотапшыру; ***программа радиовещания*** — радиотапшыру программасы; 2. *собир.* радиотапшыру учреждениеләре.

**РАДИОВЕЩА'ТЕЛЬНЫЙ** *нов.*— радиотапшыру...-ы; радиотапшыручы; ***радиовещательные станции*** — радиотапшыру станцияләре (радиотапшыручы станцияләр).

**РАДИОВОЛНА'** *ж. физ. тех.*— радиодулкын, радио дулкыны (радио тапшыру вакытында пространствога тарала торган электромагнит дулкыннар).

**РАДИОВЫ'ШКА** *спец.*— радио вышкасы (радио дулкыннары тарату һәм тоту өчен махсус биек антенна).

**РАДИОГАЗЕ'ТА** *ж.*— радиогазета (1. радиога караган мәсьәләләр языла торган газета; 2. радио аша тапшырыла торган газета).

**РАДИОГРА'ММА** *ж.*— радиограмма, радиохәбәр (радио аша бирелгән хәбәр).

**РАДИОГРА'ФИЯ** *ж. мн.* нет, *спец.*— радиография (үтә күренми торган әйберләр

аркылы рентген нурлары ярдәмендә рәсемгә төшерү).

**РАЗВЕРТЫВАНИЕ** *ср. мн.* нет — 1. җәелдерү, үстерү; *развёртывание профсоюзной работы* — профсоюз эшен җәелдерү; 2. *перен.* киңәйтү, көчәйтү, арттыру; алга җибәрү; алга китү, киң колач алу; *развёртывание школьной сети* — мәктәпләр челтәрен киңәйтү; *развёртывание товарооборота* — товар әйләнешен арттыру; *развёртывание социалистического строительства* — социалистик төзелешнең киң колач алуы; 3. *воен.* җәю, җәелдерү; *развёртывание войсковых частей* — (сугышка керү өчен) хәрби частьларны фронт буенча җәю. ◇ **Развёртывание сюжета** *лит.* — сюжет җәелеше.

**РАЗВЁРТЫВАТЬ** *несов.* — к. развернуть.

**РАЗВЁРТЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. развернуться; 2. *мат.* җәелү (җәелмә төзеп булу, сызып булу); *поверхность шара не развёртывается* — шар өслегенең җәелмәсен төзеп булмый.

**РАЗВЁРТЫВАЮЩИЙСЯ**: развёртывающаяся поверхность *мат.* — җәелмәле өс-

лек (ягъни җәелмәсен төзеп була торган өслек, *мәс.* конус, цилиндр өслеге).

**РАЗВЕ'РЧИВАТЬ** *несов.*— к. развертеть.

**РАЗВЕ'РЧИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. развертеться; 2. *страд.* борып бушайтылу, зурайтылу.

**РАЗВЕ'С** *м.*— 1. *только ед.* ваклап үлчәү, бүлеп үлчәп кую (*мәсәлән*, шикәрне); 2. *торг. устар.* үлчәү герләре.

**РАЗВЕСЕЛИ'ТЬ** *сов.*— күңелен ачу, күңелен күтәрү, кәефен күтәрү; *я старался развеселить тебя* — мин синең күңелеңне ачарга тырыштым.

**РАЗВЕСЕЛИ'ТЬСЯ** *сов.* — кәефләнү, кәефләнеп (күңелләнеп) китү; күңел ачылу, күңел күтәрелеп китү.

**РАЗВЕСЁЛЫЙ** *простореч.*— бик күңелле, шат (күр) күңелле; *развесёлый парень*— шат күңелле егет; *развесёлая компания* — бик күңелле компания.

**РАЗВЕСЕЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. развеселить.

**РАЗВЕСЕЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— к. развеселиться.

**РАЗВЕ'СИСТЫЙ** — салынкы ботаклы, салынып тора торган; тармакланып (җәелеп, таралып) үскән; *развесистые ивы* — салынкы ботаклы таллар. ◇ **Развесистая клюква** — „ипи агачы" (күрмәгән-белмәгән нәрсә турында сөйләүчедән көлеп әйтелә).

**РАЗВЕ'СИТЬ** *сов.*— 1. элү, элеп чыгу; *развесить картины* — картиналарны элеп чыгу; *развесить бельё* — кер элү; 2. таралып (тармакланып, җәелеп) үсү; җәеп җибәрү; *берёза развесила свои ветви* — каен ботакларын җәеп җибәргән; 3. үлчәп бүлү, бүлеп кую, ваклап үлчәү; *развесить чай* — чәйне үлчәп бүлеп кую. ◇ **Развесить уши** *разг. фам. ирон.*— авызын ачып тыңлап тору, колагын торгызып тыңлап тору.

**РАЗВЕ'СИТЬСЯ** *сов.*— 1. *разг.* (төрле якка) салынып төшү, җәелеп үсү; *над прудом развесилась ива* — талның ботаклары буа өстенә салынып төшкән (ягъни бик җәелеп үскән); 2. *разг.* эленү, элеп куелу, элеп куелган булу; 3. *разг.* үлчәп куелу; үлчәп бүленү; ваклап үлчәнү.

**РАЗВЕ'СКА** *ж. мн.* нет — к. развесить 1, 3; *развеска лекарства* — дару үлчәп бүлү; *чай собственной развески* (или *развеса*) — кибеттә үлчәп төргән чәй (ягъни фабрикадан төрмичә кайтарылган чәй).

**РАЗВЕСНО'Й** — үлчәп сатыла торган (данәләп түгел); *развесное печенье* — үлчәп сатыла торган печенье.

**РАЗВЕ'СОЧНЫЙ** *спец.*— үлчәү...-ы, үлчәп бүлү (үлчәп төрү) ...-ы; *развесочный цех* — үлчәп төрү цехы (фабрикада).

**РАЗВЕСТИ'** I *сов.*— 1. тарату, таратып чыгу, илтеп кую; *развести детей по домам* — балаларны өйләренә илтеп кую; 2. *воен.* кую, куеп чыгу; *развести часовых*— часовойлар куеп чыгу; 3. (бер-берсеннән) аеру, ерагайту; *судьба развела друзей* — язмыш дусларны аерды; 4. аеру, аерып җибәрү; *развести супругов* — ир белән хатынны аеру; 5. *безл. обл.* чатнау, ярылу, яргалану, чәрдәкләнү, ватылу; *лёд развело* — боз яргаланган; 6. *спец.* ике якка аеру, аерып ачу; як-якка ачып кую, күтәреп кую; *развести мост* — күперне ачып кую, күтәреп кую (*мәсәлән*, пароход үтеп китсен өчен); 7. развод ясау, тешләрен аеру; *развести пилу* — пычкының тешләрен аеру (як-якка бераз каерып чыгу); 8. *перен. устар.* туктату, юкка чыгару; *развести чей-н. спор* — бәхәсне туктату; 9. эретү, су кушу, сыегайту; изү; *развести порошок водою (в воде)* — порошокны суда эретү; *развести спирт* — спиртка су кушу; 10. ягу, ягып (яндырып) җибәрү; *развести огонь* — ут ягу. ◇ **Развести пустые разговоры** — сүз боткасы куерту. **Развести канитель**— юк белән маташу, эшне озакка сузу, бер дә юкка эш арттыру. **Развести чепуху**— юк нәрсә сөйләү. **Развести руками** — кулларын җәю, авызын ачып калу (нишләргә белми аптырап калу, хәйран калу).

**РАЗВЕСТИ'** II *сов.*— үрчетү, асрау; үстерү, игү; *развести скот* — мал үрчетү, мал асрау; *развести фруктовый сад* — җимеш бакчасы үстерү.

**РАЗВЕСТИ'СЬ** I *сов.*— 1. (*о супругах*) аерылу, аерылышу; *развестись с женой* — хатын белән аерылышу; *развестись с мужем* — ирдән аерылу; 2. *разг.* (*раствориться*) эрү, изелү, сыегаю, сыеклану.

**РАЗВЕСТИ'СЬ** II *сов.*— үрчү, күбәю, басу; күбәеп китү, басып китү; *в доме развелось много мух* — өйдә бик күп чебен үрчегән (өйне чебен баскан).

**РАЗВЕ'СЧИК** *м.*, **РАЗВЕ'СЧИЦА** *ж.*, *спец.*— үлчәүче, үлчәп торучы (кибеттә азык-төлекне).

**РАЗВЕТВИ'ТЬ** *сов. книж.*— 1. тармакландыру, тармакларга аеру (*мәсәлән*, тимер юлны); 2. *перен.* бүлекчәләр ачу; *разветвить отделения кооперации по районам* — районнарда кооперациянең бүлекчәләрен ачу.

**РАЗВЕТВИ'ТЬСЯ** *сов. книж.*— 1. тармаклану, тармакланып китү; аерылу, аерылып китү; тармакларга бүленү; *ручей разветвился* — инеш тармакланып киткән; *дорога разветвилась* — юл аерылып китте; 2. *перен.* бүлекчәләре ачылу; киңәю, киң җәелеш (таралыш) алу; *кооперация разветвилась* — кооперация киң җәелеш алды (яңа бүлекчәләре ачылды).

**РАЗВЕТВЛЕ'НИЕ** *ср. книж.*— 1. *только ед.* к. разветвить, разветвиться; 2. тармакланган (аерылган, бүленгән) урын; *у разветвления дороги* — юл икегә аерылган төштә (юл чатында, юл аермасында); 3. тармак, бүлек, бүлекчә.

**РАЗВЕТВЛЁННЫЙ** — күп тармаклы, тармакланган, (киң) җәелгән; (күп) бүлекләре булган; *широко разветвлённая организация* — күп тармаклы оешма (ягъни бик күп бүлекчәләре бар).

**РАЗВЕТВЛЯ'ТЬ** *несов. книж.*— к. разветвить.

**РАЗВЕТВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. книж.*— 1. к. разветвиться; *здесь дорога разветвляется* — бу төштә юл икегә аерыла (тармаклана); 2. *страд.* тармакландырылу, киң җәелдерелү, киңәйтелү.

**РАЗВЕ'ШАННЫЙ** — эленгән; элеп (асып) куелган; эленеп куелган (мәсәлән, кер).

**РАЗВЕ'ШАТЬ** *сов.*— таратып элү, (төрле урынга) элеп бетерү, (төрле урыннарга) элеп кую, элеп чыгу; *развешать картины*— картиналарны элеп чыгу.

**РАЗВЕ'ШЕННЫЙ** — ваклап үлчәнгән, ваклап үлчәп куелган, үлчәнеп (төреп) куелган; *чай развешен по сто грамм* — чәй йөзәр грамм итеп үлчәнеп куелган.

**РАЗВЕ'ШИВАТЬ** *несов.*— к. развесить, развешать.

**РАЗВЕ'ШИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. развеситься; 2. *страд.* элеп бетерелү, таратып эленү; 3. *страд.* бүлеп үлчәнү.

**РАЗВЕ'ЯТЬ** *сов.*— 1. тарату, таратып бетерү; куу, (җилгә) очыру; *ветер развеял облака* — җил болытларны таратып (куып) бетерде; 2. җилбердәтү; җилфердәтеп җибәрү; *ветер развеял флаги* — җил флагларны җилфердәтеп җибәрде; 3. туздыру, тузгыту; тузгытып җибәрү (бетерү); *ветер развеял её волосы* — җил аның чәчен тузгытып җибәрде; 4. *перен.* бетерү, тарату, юкка чыгару, күңелдән чыгару; таратып җибәрү; *развеять сомнения* — шик-шөбһәләрне тарату, күңелдән чыгарып ташлау. ◇ **Развеять в прах** — көлен күккә очыру, җилгә очыру, юкка чыгару.

**РАЗВЕ'ЯТЬСЯ** *сов.*— 1. таралу, таралып бетү, очып бетү (җил белән); *пыль развеялась* — тузан таралып бетте; 2. тузгу, сибелү; *волосы развеялись от ветра* — җилдән чәчләре тузгып китте; 3. *перен.* таралу, юкка чыгу, бетү; *тоска его развеялась* — аның кайгысы таралды; *все опасения развеялись в прах* — барлык шикләнүләр юкка чыкты.

**РАЗВИВА'ТЬ** *несов.*— к. развить.

**РАЗВИВА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. развиться; *ребёнок развивается* — бала ачылганнан ачыла бара; *хлеба хорошо развиваются*— икмәкләр яхшы үсә; 2. *страд.* киңәйтелү, җәелдерелү, үстерелү, алга җибәрелү; алга сөрелү.

**РАЗВИЗЖА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— чыелдау, чәрелдәү, чыелдап җибәрү; чыр-чу күтәрү; чырыйлап кычкырып җибәрү.

**РАЗВИ'ЛИНА** *ж.*, **РАЗВИ'ЛКА** *ж.*, *обл.*— 1. ять, чат (сәнәктә); аерылы ботак, чатлык (агачта); 2. юл чаты, юл аермасы; 3. *бот.* сәнәкчә (чәчәк төркеме).

**РАЗВИ'ЛИСТЫЙ** *обл.* — тармаклы, ботаклы; япьле, чатлы, (ике яки берничә) аерылы.

**РАЗВИ'ЛЬЕ** *ср. обл.*— юл чаты, юл аермасы.

**РАЗВИНТИ'ТЬ** *сов.*— 1. винтны борып алу, борып чыгару; сүтеп ташлау; *развинтить части машины* — (винтларын борып алып) машинаны сүтеп ташлау; 2. *перен. просторечь.* бозу, чыгырдан чыгару, кәефне бозу (кыру, җибәрү).

**РАЗВИНТИ'ТЬСЯ** *сов.*—1. бушаю, какшау, винтлары бушаю; *части развинтились* — частьлары бушайган (селкенә, нык түгел); 2. *перен. разг.* бозылу, какшау, ватылу, чыгырдан чыгу; тәртипсезләнү; *нервы развинтились* — нервлар какшаган.

**РАЗВИ'НЧЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.*— 1. какшаган булу, какшаганлык; *развинченность нервов* — нервларның какшаганлыгы; 2. (*о походке*) алпан-тилпән йөреш.

**РАЗВИ'НЧЕННЫЙ** — 1. бушайган, сүтелгән; винтлары борып алынган, винты бушайган; 2. *перен.* какшаган, ватылган, арыган, көче беткән, эштән чыккан. ◇ **Развинченная походка** *разг.*— алпан-тилпән йөреш.

**РАЗВИ'НЧИВАТЬ** *несов.*—к. развинтить.

**РАЗВИ'НЧИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. развинтиться; 2. *страд.* сүтелү, таратылу (винтлары борып алынып).

**РАЗВИРА'ТЬСЯ** *несов.*— к. разовраться.

**РАЗВИСА'ТЬ** *несов. просторечь.*— к. развиснуть.

**РАЗВИ'СНУТЬ** *сов. просторечь.*— к. развеситься 1.

**РАЗВИ'ТИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— 1. к. развить-развивать; 2. к. развиться-развиваться; 3. үсеш, алга китеш, алга барыш, алгарыш; *развитие промышленности* — промышленностьның үсеше; 4. *филос.* үсеш, үсеш-үзгәреш (бер сыйфаттан икенче сыйфатка күчү); 5. аң үсеше, аң-белем дәрәҗәсе. ◇ **Развитие фигур** *шахм.*— шахмат фигураларын уенга кертү.

**РАЗВИТО'Й** — 1. үскән, алга киткән; *развитая промышленность* — алга киткән промышленность; 2. аңлы, белемле, мәгълүматлы; ачык фикерле; җитлеккән (рухи һ. б. яктан); *развитой человек* — аңлы кеше; *политически развитой человек* — политик яктан җитлеккән кеше; 3. *в знач. сказ.* киң таралган, җәелгән; күп (еш) очрый; *в капиталистических странах развита безработица* — капиталистик илләрдә эшсезлек киң таралган.

**РАЗВИ'ТЫЙ** — 1. сүтелгән; *развитая верёвка* — сүтелгән бау; 2. к. развитой 2.

**РАЗВИ'ТЬ** *сов.*— 1. сүтү, язу, сүтеп тарату; *развить верёвку* — ишкән бауны сүтү; *развить пружину* — пружинаны язу (турайту); *развить волосы* — чәч толымын сүтеп тарату; 2. үстерү, көчәйтү, ныгыту; арттыру; *развить мускулы* — мускулларны ныгыту; *развить интерес* — кызыксынуны арттыру (уяту, үстерү); 3. алга җибәрү, камилләштерү, үстерү; *развить промышленность* — промышленностьны алга җибәрү; 4. җәелдерү, җәеп җибәрү, киңәйтү; *развить агитацию* — агитацияне җәелдереп җибәрү; 5. тизлек арттыру, тизлек алу; *паровоз развил большую скорость* — паровоз гаять зур тизлек алды; 6. зиһенен ачу, аның үстерү; *постоянное общение со старшими рано развило ребёнка* — олылар белән даими аралашу баланың аңын бик иртә үстерде; 7. (берәр фикерне дәвам итеп) киңәйтү, тулыландыру, үстереп җибәрү; алга сөрү.

**РАЗВИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. сүтелү, таралу; *верёвка развилась* — (ишкән) бау сүтелде; 2. үсү, ныгу; җитлегү; *мускулы развились*— мускуллары ныгыды; 3. туу, арту; урнашу;

*у детей развился интерес к искусству* — балаларда сәнгать белән кызыксыну артты; 4. үсү, алга китү, киң үсеш алу; *развилась социалистическая промышленность* — социалистик промышленность алга китте (киң үсеш алды); 5. таралу, җәелү; *не дать развиться эпидемии* — эпидемиянең таралуына юл куймаска; 6. рухи үсү, алга китү, зиһене ачылу, рухи житлегү; *мальчик очень развился за время пребывания в школе* — мәктәптә укыган дәверендә малай рухи яктан бик нык үсте; 7. арту; *при спуске с горы развилась большая скорость* — таудан төшкәндә тизлек бик нык артты.

**РАЗВИХЛЯ'Й** *м. просторeч. обл.*— к. разгильдяй.

**РАЗВЛЕКА'ТЕЛЬНЫЙ** *разг.*— күңел ача торган, күңел юаткыч; мавыктыргыч, күңелле, кызык(лы); *развлекательная книга* — кызыклы китап; *развлекательные игры* — күңел ача торган уеннар.

**РАЗВЛЕКА'ТЬ** *несов.*— к. развлечь.

**РАЗВЛЕКА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. развлечься; 2. *страд.* юатылу.

**РАЗВЛЕЧЕ'НИЕ** *ср.*— 1. *только ед. книж.* к. развлечь; 2. уен-көлке, күңел ачу, мавыгу, юаныч; *массовые развлечения* — күмәк күңел ачулар; *невинное развлечение* — зарарсыз мавыгу; *единственное развлечение* — бердәнбер юаныч.

**РАЗВЛЕ'ЧЬ** *сов.*— 1. күңелен ачу, күңелен күтәрү; юату; *развлечь ребёнка* — баланы юату; 2. мавыктыру, кызыксындыру; күңелен табу, кайгысын тарату; *после тяжёлой потери ничто не могло его развлечь* — авыр югалтудан соң аны һичнәрсә кызыксындыра алмады.

**РАЗВЛЕ'ЧЬСЯ** *сов.* — 1. күңел ачу, хозурлану; *хочется развлечься и отдохнуть* — бераз күңел ачасы һәм ял итәсе килә; 2. юану, мавыгу; юаныч табу, кызык табу (берәр нәрсә белән шөгыльләнеп кайгыны тарату).

**РАЗВО'Д** I *м.*— 1. к. развести I в 1, 2, 6, 7 знач.; *развод часовых* — сакчыларны постка куеп чыгу (алмаштыру); *развод пилы* — пычкының разводы; *развод мостов* — күперне аерып ачып кую, күперне күтәреп кую; 2. аеру, аерылу, аерылышу; *дать развод* — аеру, аерып җибәрү; 3. *только мн.* бизәк, парча, бизәкле рәсем; *скатерть с голубыми разводами* — зәңгәр бизәкләр төшкән эскәтер; 4. *спец. только мн.* үрәчә (чанада); *разводы у саней* — чана үрәчәләре. ◇ **Чернильные разводы** (*на столе*) — (өстәлдәге) кара таплары.

**РАЗВО'Д** II *м.*— үрчетү, үрчем; *оставить на развод* — үрчемгә калдыру (нәселгә калдыру).

**РАЗВОДИ'ТЬ** I *несов.*— к. развести I.

**РАЗВОДИ''ТЬ** II *несов.*— к. развести II.

**РАЗВОДИ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. развестись I, II; 2. *страд.* үрчетелү.

**РАЗВО'ДКА** *ж.*— 1. *мн.* нет, к. развести I в 6, 7 знач.; *разводка пилы* — пычкыга развод ясау; *разводка моста* — күперне күтәрү; 2. *тех.* развод ачкычы (развод ясау коралы); 3. *спец.* (тартып, сугып) җәю, сузу, тигезләү (мәсәлән, тире, күн, калай һ. б. ш. кебек әйберләрне); 4. *просторeч. устар.* аер(ыл)ган хатын.

**РАЗВО'ДНАЯ** *в знач. сущ. ж. разг.*— аерылышу таныклыгы (аерылышу турындагы таныклык).

**РАЗВОДНО'Й** — 1. аера торган, развод ясый торган; җәелмәле; *разводной ключ* — а) развод ясый торган ачкыч, развод ачкычы; б) җәелмәле ачкыч (төрле гайкага яраралык булып ачыла торган ачкыч); 2. аерыла торган; күтәрелә торган; *разводной мост* — күтәрелә торган күпер.

**РАЗВО'ДНЫЙ** — аерылышу...-ы; аерылышу турындагы; *разводное свидетельство* — аерылышу таныклыгы.

**РАЗВО'ДЧИК** *м. спец.*— 1. *просторeч.* үрчетүче, үстерүче; *разводчик цветов* — чәчәкләр үстерүче; 2. *спец.* развод ясаучы; күпер ачучы (күтәртүче).

**РАЗВО'ДЬЕ** *ср.*— 1. *обл.* язгы ташу, язгы ташкын; 2. күзләвек (бозлар арасындагы ачыклык, су).

**РАЗВОДЯ'ЩИЙ** — 1. аеручы; таратучы; күтәрүче, ачучы; эретүче, сыегайтучы; (ут) ягучы; үрчетүче, үстерүче, асраучы; 2. *в знач. сущ. м. воен.* разводящий, каравыл куючы (каравылда торучыларны постларына куючы һәм алмаштыручы).

**РАЗВОЕВА'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.* — гаугa (җәнҗал) куптару, шау-шу күтәрү.

**РАЗВО'З** *м. мн.* нет — (йөкләрне) ташу, тарату; *развоз товаров по магазинам* — товарларны магазиннарга ташу. ◇ **В развоз (торговать, продавать)** *торг.*— төрле урыннарга илтеп (сату, йөреп сәүдә итү).

**РАЗВОЗЖА'ТЬ** *сов. обл.*— дилбегәсен чишү; дилбегәсеннән ычкындыру; дилбегәсен чишеп алу.

**РАЗВОЗИ'ТЬ** *несов.*— ташу, ташып йөрү, таратып йөрү (йөккә төялгәнне).

**РАЗВОЗИ'ТЬСЯ** I *несов. страд.*— таратылу; ташылу, ташып куелу (атта, машинада һ. б. ш.).

**РАЗВОЗИ'ТЬСЯ** II *сов. разг.*— кайнаша башлау; чыр-чу килә башлау; мәш килү, ыгы-зыгы килү (куптару); *дети развозились в саду* — бакчада балалар кайнаша башлады.

**РАЗВО'ЗКА** *ж. просторeч.*— 1. к. развоз; 2. (товар ташый торган) арба.

**РАЗВОЗНО'Й**: **развозная торговля** — йөреп (йөктән) сәүдә итү; **развозные товары** — йөреп (йөктән) сатыла торган товарлар.

**РАЗВО'ЗЧИК** *м.*, **РАЗВО'ЗЧИЦА** *ж. спец.* — ташучы, таратучы; йөк ташучы, йөк йөртүче, олау йөртүче; йөктән сатучы, йөреп сатучы (йөктән сатып яки таратып йөрүче).

**РАЗВО'Й** *м. спец.*— 1. (чорналганны) сүтү; 2. сүтелә торган йомгак, чорнам (йон, җеп һ. б. ш. материаллардан).

**РАЗВОЛА'КИВАТЬ** *несов. обл.*— к. разволочь.

**РАЗВОЛА'КИВАТЬСЯ** *несов. обл.*— аязу, болытлар таралу, болытлардан арчылу; *к вечеру стало разволакиваться* — кичкә таба көн аяза башлады.

**РАЗВОЛНОВА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. дулкын куптару, дулкын күтәрү; *ветер разволновал море* — жил дингездә дулкын күтәрде; 2. *перен.* дулкынландырып җибәрү; тынычсызлау, тынычсызландыру, борчу; *эта весть разволновала его* — бу хәбәр аны дулкынландырып җибәрде.

**РАЗВОЛНОВА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. (*о море, жидкости*) дулкынлану, дулкын күтәрелү; 2. *перен.* бик нык дулкынлану, бик нык борчылу, тынычсызлану; *напрасно разволновался* — юкка борчылганмын.

**РАЗВОЛО'ЧЬ** *сов. обл.* — 1. (өстерәп) төрле якка ташып бетерү, ыргытып бетерү; сүтеп (таратып) ташлау; 2. *безл.* куып бетерү, таратып бетерү; *тучи ветром разволокло* — жил болытларны таратып бетерде.

**РАЗВОПИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — ачы тавыш белән кычкыра башлау, акыра башлау, үкереп елау, акырып елап җибәрү.

**РАЗВОРА'ЧИВАТЬ** *несов. разг.* — 1. к. разворотить; *разворачивать мостовую* — урамга җәелгән ташларны актарып ташлау; 2. к. разворочать; 3. *простореч.* ачу; *разворачивать пакет* — пакетны ачу; 4. җәелдерү; *разворачивать массовую работу* — масса эшләрен җәелдерү.

**РАЗВОРА'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг. страд.* актарып ташлану; 2. *простореч.* к. развёртываться.

**РАЗВОРА'ШИВАТЬ** *несов. разг.* — к. разворошить.

**РАЗВОРА'ШИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — кабартылу, таратылу; таратып җәелү, таратып ташлану; туздырып (актарып) ташлану.

**РАЗВОРКОВА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. (*о голубях*) гөр-гөр килү, гөрләшү, гөрли (гөрләшә) башлау; 2. *перен. фам.* сүз белән мавыгып китү, сүзгә бирелеп китү; сөйләшә-сөйләшә онытылып китү; гөрләшә башлау, гөрләшеп туя алмау.

**РАЗВОРОВА'ТЬ** *сов. разг.* — урлап бетерү, урлап ташып бетерү.

**РАЗВОРО'ВЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. разворовать.

**РАЗВОРО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — урланып бетү, урлап ташып бетерелү.

**РАЗВОРО'Т** *м.* — 1. актарып ташлау, сүтеп ташлау; *разворот мостовой* — урам ташын актарып ташлау; 2. *мн.* нет, к. развернуть 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7, 8, 9; 3. к. развернуться 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7; 4. *спец.* (килгән ягына таба) әйләнеп борылу; *разворот самолёта* — самолётның әйләнеп борылуы; 5. *спец. тип.* разворот (газета яки журналда ике битнең тоташ бер бит итеп рәсемләнеп бирелүе).

**РАЗВОРОТИ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. актарып ташлау, таратып ташлау; астын-өскә китерү; *разворотить кучу камней* — таш өемен актарып ташлау; 2. җимерү, җимереп ташлау; *льдом разворотило деревянный мост* — боз агач күперне җимереп ташлаган; 3. *обл. безл.* калҗай(т)у, калҗайтып бетерү; *жаром доску разворотило* — кызудан такта калҗайган; 4. *простореч. вульг.* (авыз-борынын) җимерү, гарипләү, имгәтеп бетерү.

**РАЗВОРО'ЧАТЬ** *сов. простореч.* — актарып (бутап) бетерү; таратып (туздырып) ташлау; *разворочать бумаги в столе* — өстәл эчендәге кәгазьләрне актарып бетерү.

**РАЗВОРО'ЧАТЬСЯ** *сов. простореч.* — (бер яктан икенче якка) әйләнү, әйләнә башлау; *спи, что ты разворочался?* — йокла, нәрсә бер яктан икенче якка әйләнәсен?

**РАЗВОРОШИ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. әйләндерү, кабарту, таратып ташлау; *разворошить сено* — печәнне таратып ташлау (киптерү өчен); 2. туздырып (актарып) ташлау; *разворошить муравейник* — кырмыска оясын туздырып ташлау; 3. *перен.* (элекке хатирәләрне) искә (хәтергә) төшерү; *разворошить забытые воспоминания* — онытылган истәлекләрне искә төшерү (кузгату, уяту).

**РАЗВОРЧА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — бертуктаусыз мыгырдана башлау, сукрану.

**РАЗВРА'Т** *м. мн.* нет — 1. фәхеш(лек), җенси бозыклык, җенси таркалу; уйнаш; *предался разврату* — фәхеш юлына басты; 2. *книж.* әхлаксызлык, азгынлык, бозыклык; 3. иркәләп бозылганлык.

**РАЗВРАТИ'ТЕЛЬ** *м. книж.* — аздыручы, бозыклыкка өйрәтүче, юлдан яздыручы.

**РАЗВРАТИ'ТЬ** *сов.* — 1. аздыру, җенси яктан таркату, фәхеш юлына бастыру; 2. бозыклыкка өйрәтү, бозыклыкка өстерәү, бозу; юлдан яздыру, явыз юлга керту, әхлаксызлыкка өйрәтү; 3. *простореч.* артык бай (иркен, зиннәтле) тормышка өйрәтеп бозу, иркәләп бозу.

**РАЗВРАТИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. азу, бозыклыкка бирелү; 2. юлдан язу, әхлаксызлану; 3. (зиннәтле, иркен тормыштан) бозылу, иркәләнеп бетү; *развратиться от безделья* — эшсез ятудан бозылу.

**РАЗВРА'ТНИК** *м.* — бозык, азгын кеше; уйнашчы.

**РАЗВРА'ТНИЦА** *ж.* — бозык, азгын хатын; уйнашчы хатын; фахишә.

**РАЗВРА'ТНИЧАТЬ** *несов. разг.* — фәхешлек итү, уйнашлык итү.

**РАЗВРА'ТНЫЙ** — азгын, бозык, фахиш; *развратный человек* — азгын кеше; *развратные мысли* — бозык фикерләр.

**РАЗВРАЩА'ТЬ** *несов.* — к. развратить.

**РАЗВРАЩА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. развратиться; 2. *страд.* аздырылу, җенси таркатылу, бозыклыкка өйрәтелү, юлдан яздырылу.

**РАЗВРАЩЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — к. развратить, развратиться.

**РАЗВРАЩЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — бозылганлык, азганлык; җенси таркалганлык, әхлаксызлык.

**РАЗВРАЩЁННЫЙ** — азгын, бозык, мораль таркалган, җенси таркалган; әхлаксыз; *развращённый человек* — бозык кеше.

**РАЗВЫ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — 1. улый башлау, уларга тотыну (керешү); туктаусыз улау; *собаки развылись* — этләр уларга тотындылар; 2. *перен. пренебр.* үкерү, үкереп

елап җибәрү, акырып елый башлау, туктаусыз үкерү.

**РАЗВЬЮ'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. развьючить.

**РАЗВЬЮ'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. развьючиться; 2. *страд.* (ишәк, дөя кебекләрнең) йөге бушатылу, йөге алыну, йөге төшерелү.

**РАЗВЬЮ'ЧИТЬ** *сов.* — йөген бушату, йөген алу, йөген төшерү, йөген салдыру (ат, дөя, ишәк өстеннән).

**РАЗВЬЮ'ЧИТЬСЯ** *сов.* — йөктән бушау, йөге төшү, йөген ташлау.

**РАЗВЯЗА'ТЬ** *сов.* — 1. (бәйләгәнне) чишү, сүтү; чишеп ычкындыру, ычкындырып җибәрү; сүтеп (чишеп) ачу; *развязать шнурки ботинок* — ботинка шнурларын чишү; *развязать пакет* — пакетны (чишеп) ачу; 2. *перен. разг.* чишү, хәл итү, ачыклау; аныклау, *развязать спор* — бәхәсне хәл итү; 3. *перен. разг.* иркенлек бирү, кулны чишеп җибәрү; *такой исход дела меня развяжет* — эшнең болай тәмамлануы минем кулымны чишеп җибәрер; 4. *перен.* җәеп җибәрү, юл ачу, мөмкинлек бирү; *развязать творческую инициативу рабочих* — эшчеләрнең иҗади инициативасына юл ачу; 5. *перен.* башлау, башлап җибәрү, ачып җибәрү; *агрессивные силы стремятся развязать войну* — агрессив көчләр сугыш ачып җибәрергә омтылалар. ◇ **Развязать руки** — юл ачу, үз ихтыярына (иркенә) кую. **Развязать язык** — 1) телен чишеп җибәрү, телен ачтыру (сөйләтү). 2) теле ачылып китү (күп сөйли башлау).

**РАЗВЯЗА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. чишелү, сүтелү, ачылу; чишелеп китү; *лента развязалась* — тасма чишелде; *пакет развязался* — пакет ачылып китте; 2. *перен разг.* котылу, ычкыну, бушау; *развязаться с каким-н. делом* — бер-бер эштән котылу. ◇ **Язык развязался** *разг.* — теле чишелде.

**РАЗВЯ'ЗКА** *ж.* — 1. *разг.* к. развязать 1, 2, 4; 2. *лит.* чишелеш; *развязка драмы* — драманың чишелеше; 3. тәмамланыш, тәмамлану; соң, ахыр, нәтиҗә; *дело идёт к развязке* — эш ахырына җитеп килә; *развязка повести* — повестьның тәмамланышы.

**РАЗВЯ'ЗНО** *нареч.* — әдәпсез (оятсыз, тәкәллефсез) рәвештә; *развязно держать себя* — үзен әдәпсез (рәвештә) тоту.

**РАЗВЯ'ЗНОСТЬ** *ж. мн.* нет — әдәпсезлек, затсызлык, тупаслык; тыйнаксызлык, тотнаксызлык, әрсезлек (үзен артык иркен, искитмичә тотучанлык); *развязность манер* — кыланышларының тупаслыгы.

**РАЗВЯ'ЗНЫЙ** *неодобр.* — әдәпсез, тотнаксыз, тартынусыз; оятсыз, затсыз, тупас, әрсез, артык иркен; *развязные манеры* — артык иркен кыланышлар (ягъни әдәп чикләренә сыймый торган тупас кыланышлар).

**РАЗВЯ'ЗЫВАТЬ** *несов.* — к. развязать.

**РАЗВЯ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. развязаться; 2. *страд.* хәл ителү, ачыклану.

**РАЗГАДА'ТЬ** *сов.* — 1. (уйлап) табу, җавабын табу; чишү, чишелешен табу; ачу; *разгадать шараду* — шараданы чишү; 2. төшенү, аңлау, тану; төшенеп (аңлап, белеп) алу; *с трудом разгадал, что это значит* — моның мәгънәсенә көчкә төшендем.

**РАЗГА'ДКА** *ж. мн.* нет — 1. к. разгадать; 2. җавап, чишелеш (табышмак, баш ваткыч һ. б. ш. кебекләрнең); *у этой загадки несколько разгадок* — бу табышмакның берничә җавабы бар.

**РАЗГА'ДЧИК** *м.*, **РАЗГА'ДЧИЦА** *ж.* *разг.* — чишүче, җавап табучы, җавап бирүче (табышмак һ. б. ш. кебекләргә); *он искусный разгадчик шарад* — ул шарадаларны оста чишүче.

**РАЗГА'ДЫВАТЬ** *несов.* — 1. к. разгадать; 2. *обл.* күп уйланып тору, исәпләп тору, икеләнеп уйлап тору; *нечего разгадывать, надо действовать* — күп уйлап тормаска, хәрәкәт итәргә кирәк.

**РАЗГА'ДЫВАТЬСЯ** *несов.* *страд.* — (җавабы) табылу, чишелү, ачылу.

**РАЗГА'Р** *м. мч.* нет — иң кызу чак, иң кызган чак; иң көчле чак; янып торган вакыт; *уборка была в самом разгаре* — урып-җыюның иң кызган чагы иде.

**РАЗГИ'Б** *м. разг. спец.* — 1. к. разогнуть; 2. язылган, турай(тыл)ган, төзәйтелгән урын; *на самом разгибе* — нәкъ турайган урынында.

**РАЗГИБА'ТЬ** *несов.* — к. разогнуть. ◇ **Не разгибая спины работать** — баш күтәрмичә эшләү.

**РАЗГИБА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. разогнуться; 2. *страд.* турайтылу, төзәйтелү.

**РАЗГИЛЬДЯ'Й** *м. разг. пренебр.* — җобалгы, тәртипсез, ваемсыз, ачык авыз; *нам не нужны разгильдяи* — безгә җобалгы кешеләр кирәкми.

**РАЗГИЛЬДЯ'ЙНИЧАТЬ** *несов. разг. пренебр.* — эшлексез булып йөрү, ваемсыз (ачык авыз) булу; ялкауланып йөрү.

**РАЗГИЛЬДЯ'ЙСТВО** *ср. мн.* нет, *разг. пренебр.* — җобалгылык, тәртипсезлек, ачык авызлык, ваемсызлык.

**РАЗГЛАГО'ЛЬСТВОВАНИЕ** *ср. разг. ирон.* — к. разглагольствовать.

**РАЗГЛАГО'ЛЬСТВОВАТЬ** *несов. разг. ирон.* — күп сөйләнү, күп сөйләнеп вакыт үткәрү; гәп (сафсата, фәлсәфә) сату; сүзне озынга сузу.

**РАЗГЛА'ДИТЬ** *сов.* — 1. үтүкләү, шомарту, тигезләү; *разгладить платье* — күлмәкне үтүкләү; 2. бетерү, юк итү; *разгладить морщины* — җыерчыкларны бетерү.

**РАЗГЛА'ДИТЬСЯ** *сов.* — 1. тигезләнү, шомару, үтүкләнү; *платье хорошо разгладилось* — күлмәк яхшы үтүкләнде; 2. бетү, югалу, язылу; юкка чыгу; *морщины на лбу разгладились* — маңгаендагы җыерчыклары югалган.

**РАЗГЛА'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. разгладить.

**РАЗГЛА'ЖИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. разгладиться; 2. *страд.* шомартылу, тигезләтелү, үтүкләнелү.

**РАЗГЛАСИ'ТЕЛЬ** *м. книж. неодобр.* — фаш итүче, таратучы, таратып йөрүче, гайбәтче; *разгласитель непроверенных слухов* — тикшереп дөресләнмәгән хәбәр-

ләр таратып йөрүче; *разгласитель тайны* — серне фаш итүче.

**РАЗГЛАСИ'ТЬ** *сов.*— **1.** тарату, ачу, фаш итү; халыкка белдерү; әйтеп салу, ычкындыру (әйтергә ярамаганны); *разгласить чужую тайну* — чит кешенең серен ачу; **2.** *разг. неодобр.* (булмаганны) сөйләү, халыкка тарату; хәбәр (сүз) тарату.

**РАЗГЛАША'ТЬ** *несов.*— к. разгласить.

**РАЗГЛАША'ТЬСЯ** *несов. страд.*— хәбәр таратылу, фаш ителү, сере ачылу; халыкка белдерелү.

**РАЗГЛАШЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— к. разгласить.

**РАЗГЛЯДЕ'ТЬ** *сов.*— **1.** (яхшылап карап) күрү, тану, аеру, күреп (танып) алу; *я не разглядел его в темноте* — мин аны караңгыда танып ала алмадым; **2.** *перен. разг.* (кем икәнен) белү; белеп (төшенеп, сизеп, аңлап) алу.

**РАЗГЛЯ'ДЫВАТЬ** *несов.*— жентекләп карау, текәлеп карау; танырга тырышып карау; карап (күзәтеп) тору; *разглядывать со всех сторон* — һәр яктан жентекләп карау.

**РАЗГЛЯ'ДЫВАТЬСЯ** *несов.*— карану; як-якка (тирә-якка) каранып тору.

**РАЗГНЕ'ВАННЫЙ** — ачулы, бик ачулы; ачуланган, ачуы кабарган; *разгневанный голос* — ачулы тавыш.

**РАЗГНЕ'ВАТЬ** *сов.*— ачуландыру; ачуын кабарту, ачуын китерү, ачуын кузгату.

**РАЗГНЕ'ВАТЬСЯ** *сов.*— нык ачулану, ачу кабару, ачу килү, ачу кузгалу.

**РАЗГНЕЗДИ'ТЬСЯ** *сов. спец.*— оялау, ояларга урнашу (кошлар турында).

**РАЗГОВА'РИВАТЬ** *несов.*— **1.** сөйләшү, гәпләшү; әңгәмә алып бару; *разговаривать по-русски* — рус телендә сөйләшү; **2.** *разг. ирон.* гәп сату, күп сөйләнү, сөйләнеп (лыгырдап) вакыт уздыру; *работай, некогда разговаривать*—гәп сатып (лыгырдап) торырга вакыт юк, эшлә; **3.** *разг.* карулашу, каршы сүз әйтү, каршы сөйләү; *не смей разговаривать* — каршы сүз әйтәсе (авыз ачасы) булма; **4.** *разг.* (кеше белән) сөйләшү, аралашу, мөнәсәбәттә булу; *я с тобой не разговариваю* — мин синең белән сөйләшмим (ягъни синең белән бернинди эшем юк); **5.** *простореч.* к. разговорить.

**РАЗГОВЕ'ТЬСЯ** *сов.*— **1.** *церк.* христиан динендә: авыз ачу (ураза бетеп итле азыклар ашый башлау); **2.** *перен. простореч. фам. шутл.* бераз сыйланып алу, (тәмле әйбер) ашап алу.

**РАЗГОВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— к. разговеться.

**РАЗГОВО'Р** — **1.** сөйләшү; әңгәмә, сүз, гәп; *вести разговор* — сөйләшеп утыру, сөйләшү; *запнуться в разговоре* — сүзлә төртелү; **2.** *чаще мн. разг.* сөйләнү, сөйләнүләр, тиешсез сүз сөйләү, сүз озайту; *это ещё что за разговоры?*— бу нинди сөйләвү? **3.** *разг.* сүз, гайбәт, имеш-мимеш; *да и разговору меньше будет* — аннары, сүзе дә аз булыр (имеш-мимеш сүзләр аз булыр); **4.** *обл. простореч.* әйтелеш, сөйләү рәвеше; **5.** *только мн. лит.* диалоглар, әңгәмәләр (кара-каршы әңгәмә рәвешендә язылган әсәр); *разговоры Сократа* — Сократ диалоглары (Сократ әңгәмәләре); **6.** *устар.* тел өйрәткеч.◇ **Переменить разговор** — сүзне икенчегә бору; әңгәмәне икенче якка борып жибәрү. **И разговору нет или и разговору быть не может** *(о чём) разг.*— **1.** сүз дә булуы мөмкин түгел; сүз шуның белән тәмам; **2.** үзеннән-үзе ачык (билгеле), артык сүз әйтеп торасы юк. **Без разговоров или никаких разговоров** — сүзсез, һичбер сүзсез, һичбер сүз булырга мөмкин түгел. **Только и разговору, что...**- һәркем шул турыда сөйли, һәркемнең телендә шул сүз. **Крупный разговор** — к. крупный.

**РАЗГОВОРИ'ТЬ** *сов. простореч.*— **1.** сөйләтү, сүзгә тарту, сөйләндерү; **2.** *(развлечь беседой)* сүз белән мавыктыру, юату, күңелен күтәрү; **3.** сөйләп күндерү, фикереннән (уеннан) кире кайтару; *он собирался ехать, но мы разговорили его* — ул барырга җыенган иде, ләкин без аны уеннан кире кайтардык.

**РАЗГОВОРИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— **1.** сөйләшеп китү, гәпләшеп китү, сүзгә керешеп китү, тел ачылып китү; *разговориться с соседями по вагону* — вагондагы күршеләр белән сөйләшеп китү; **2.** сүзгә мавыгып (бирелеп) китү; *разговорился и забыл о времени* — сүзгә мавыгып, вакыт узганын да оныткан.

**РАЗГОВО'РНИК** *м. спец.*— тел өйрәткеч, сөйләргә өйрәткеч (төрле темаларга сөйләшү үрнәкләре язылып, чит телне өйрәнү өчен хезмәт итә торган китап).

**РАЗГОВО'РНЫЙ**—**1.** *лингв. лит.* сөйләү (сөйләшү)...ы; сөйләү телендәге; *разговорный язык, разговорная речь* — сөйләү теле, сөйләшү теле; **2.** *простореч.* телефон...-ы; сөйләшү...-ы; *разговорная будка* — сөйләшү будкасы; **3.** *школьн.* сөйлә(ш)ү...-ы; *разговорный урок* — сөйләү дәресе.

**РАЗГОВО'РЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — сүзчәнлек, сөйләшүчәнлек, сүзчән булу; сөйләшергә яратучан (сүзгә һәвәс) булу.

**РАЗГОВО'РЧИВЫЙ** —сүзчән, сөйләмчәк; сөйләшергә яратучан, гәпләшергә яратучан.

**РАЗГОВО'РЧИК** *м. простореч. фам. пренебр.* — сөйләнү, лыгырдау, буш сүз; *прекратить разговорчики* — лыгырдауны туктатыгыз.

**РАЗГОВО'РЩИК** *м. простореч. неодобр.*— такылдык, лыгырдык, тел бистәсе.

**РАЗГО'Н** *м.*— **1.** *только ед.* к. разогнать 1, 2, 5, 6; *разгон демонстрантов полицией* — демонстрациячеләрнең полиция тарафыннан куып таратылуы (туздырылуы); **2.** *спец.* ара, аралык (гомумән бердәй ераклыкта урнаштырылган бер үк төрле әйберләр арасы); *разгон между столбами* — баганалар арасы; **3.** *плотн.* и *порт.* чөй; чөйсыман ялгау. ◇ **В разгоне** *разг.*— эшкә җибәрелгән, өйдә юк; *машины в разгоне* — барлык машиналар эшкә җибәрелгән. **Прыжок с разгона** — йөгереп килеп сикерү. **Разгона нет здесь** — монда тиз-

лекне арттырырга мөмкинлек юк (урын юк).

**РАЗГО'НИСТО** *нареч.*— сирәк итеп, сирәклә(те)п, киң ара калдырып; *разгонисто писать* — сирәк итеп язу.

**РАЗГО'НИСТЫЙ** *простореч.* — сирәк, арасы киң; киң ара калдырып язылган (басылган).

**РАЗГО'НКА** *ж. мн.* нет — 1. *просторечи.* и *спец.* к. разгон 1, 3; 2. *тех.* (чүкегәндә металлны) аркылыга җәю; 3. *хим.* кабат куу (сыекчаларны, катнашмаларны); *разгонка масел* — майларны кабат куу.

**РАЗГО'ННЫЙ:** **разгонные лошади** *спец.*— юл йөрү атлары (эшкә җигелми торган атлар); **выпить разгонную** *просторечи. фам.*— юлга чыгу алдыннан эчү, саубуллашу унае белән эчү.

**РАЗГОНЯ'ТЬ** *несов.*— к. разогнать.

**РАЗГОНЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. *разг.* к. разогнаться; 2. *страд.* куылу, туздырылу, таратылу.

**РАЗГОРА'ЖИВАТЬ** *несов.*— к. разгородить.

**РАЗГОРА'ЖИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. *разг.* к. разгородиться; 2. *страд.* бүленү, коймa (киртә) тотылу.

**РАЗГОРА'ТЬСЯ** *несов.*— к. разгореться.

**РАЗГОРЕ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. кабыну, янып китү, кабынып китү, көйрәп китү, яна башлау; *сырые дрова насилу разгорелись* — чи утын көчкә янып китте; 2. шәп яна башлау, дөрләп янып китү, дөрләп яна башлау; *костёр разгорелся* — учак дөрләп яна башлады; 3. *перен.* (көн) нык җылыну, кызу; кыздыра (җылыта) башлау; 4. *перен.* кызару, алсулану; шәфәкъ кызыллыгы күрү; *небо на востоке разгорелось* — көнчыгышта күк йөзе алсуланды; 5. *перен.* кызарып китү, кызыллык йөгерү, кып-кызыл булу; ут кебек яна башлау; *от волнения у нее разгорелись щёки* — дулкынланудан ике бите ут кебек яна башлады. ◇ **Сердце разгорелось** — йөрәк яна башлады (мәхәббәт һ. б. белән). **Спор разгорелся с новой силой** — бәхәс тагы да кызып китте. **Аппетит разгорелся** — аппетит ачылып китте. **Глаза (и зубы) разгорелись** *на что разг.*— күзләр уттай яна башлады, авызыннан сулар килде (бик кызыгуны яисә теләкне күрсәтә).

**РАЗГОРОДИ'ТЬ** *сов.*— (бүлмә) бүлү, бүлеп кую; бүлеп икегә аеру; *разгородить комнату* — бүлмәне бүлеп икегә аеру.

**РАЗГОРОДИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. бүленү, аерылу (бүлмә, коймa, киртә һ. б. ш. белән); 2. *перен. фам.* бер-береннән аерылу, ара өзелү; 3. *(разграничить обязанности)* вазифаларны бүлешү, эш даирәсен чикләү.

**РАЗГОРЯЧЁННЫЙ** — кызу, кызган; ярсу, ярсулы, ярсыган.

**РАЗГОРЯЧИ'ТЬ** *сов.*— кыздыру, ярсыту; кыздырып (ярсытып, ачуландырып) җибәрү; *разгорячить спором собеседника* — гәпләшеңне бәхәс белән кыздырып җибәрү; *разгорячить коня* — атны ярсыту.

**РАЗГОРЯЧИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. (тән) кызу, кызышу, әсселәү, әссел(не)п китү; *разгорячиться от быстрой ходьбы* — кызу йөрүдән әсселәнеп китү; 2. ярсып (кызып) китү, кабынып китү, ачулану; холыксызлану, тузыну, каны кызу; *разгорячиться из-за пустяков* — юк-барга кызып китү.

**РАЗГРА'БИТЬ** *сов.*— 1. талау, басу; талап алу, талап чыгу, талап китү, талап бетерү; *разграбить имущество* — әйберләрен талау; *разграбить лавку* — кибет басу; 2. *обл.* тырма белән тарату, таратып җәю; *разграбить сено* — печән тарату.

**РАЗГРАБЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— к. разграбить.

**РАЗГРАНИЧЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. к. разграничить, разграничи(ва)ться; 2. *книж.* чик, чикләү сызыгы.

**РАЗГРАНИ'ЧИВАТЬ** *несов.*— к. разграничить.

**РАЗГРАНИ'ЧИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. разграничиться; 2. *страд.* чик сызылу, чик билгеләнү.

**РАЗГРАНИЧИ'ТЕЛЬНЫЙ:** **разграничительная комиссия** — чик сызыгын билгеләү комиссиясе; **разграничительные столбы** — чик баганалары.

**РАЗГРАНИ'ЧИТЬ** *сов.*— 1. чик (межа, ызан) сызу; чикләрен билгеләү, чик билгеләп чыгу; *разграничить земли* — җирләрнең чикләрен билгеләп чыгу; 2. чикләү; ачыклау; бүлешү, аеру; *разграничить обязанности* — вазифаларны чикләү, вазифаларны бүлешү; *разграничить понятия* — төшенчәләрне аеру (мәгънә чикләрен төгәл билгеләү).

**РАЗГРАНИ'ЧИТЬСЯ** *сов.* — бер-берсеннән аерылу, аерымлану, аерылып чыгу; (чикләре) ачыклану, төгәл билгеләнү.

**РАЗГРАФИ'ТЬ** *сов.*—графалар сызу, сызыклар сызып чыгу; графалап чыгу, баганалап сызу; *разграфить бумагу* — кәгазьгә сызыклар сызып чыгу.

**РАЗГРАФЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. разграфить.

**РАЗГРАФЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— сызыклар сызылу, графалап чыгылу.

**РАЗГРЕБА'ТЬ** *несов.*— к. разгрести.

**РАЗГРЕБА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— көрәлү, көрәп таратылу, таратып ташланылу; *хлеб разгребается деревянными лопатами* — ашлык көшеле агач көрәкләр белән көрәп таратыла.

**РАЗГРЕСТИ'** *сов.* — 1. көрәү, көрәп тарату, көрәп ташлау; *разгрести снег* — карны көрәп ташлау; 2. тарату, таратып (чәчеп, җәеп) ташлау; таратып кую; *разгрести сено граблями* — печәнне тырма белән таратып ташлау.

**РАЗГРО'М** *м. мн.* нет — 1. к. разгромить; 2. тар-мар, тар-мар ит(ел)ү, җиң(ел)ү; *разгром армии интервентов* — интервентлар армиясенең тар-мар ителүе; *идейный разгром противника* — дошманны идея ягыннан тар-мар итү, дошманның идея ягыннан тар-мар ителүе; 3. җимереклек, хәрабәлек, вәйранлык; талану, бөлгенлек; *картина разгрома*—җимереклек картинасы. ◇ **Дома полный разгром** *разг.* — өйдә бөтен нәрсәнең асты-өскә килгән.

**РАЗГРОМИ'ТЬ** *сов.* — к. громить.

**РАЗГРУЖА'ТЬ** *несов.* — к. разгрузить.

**РАЗГРУЖА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. разгрузиться; 2. *страд.* бушатылу.

**РАЗГРУЗИ'ТЬ** *сов.* — 1. бушату, йөген алу; *разгрузить вагон* — вагонны бушату; 2. *перен. разг.* бушата төшү; эшен җиңеләйтү, эшен киметү; *разгрузить работника* — работникның эшен җиңеләйтә төшү (артык йөкләмәләрдән азат итү).

**РАЗГРУЗИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. йөктән бушау, бушап калу, йөге бушатылу; *пароход разгрузился* — пароход йөктән бушады (пароходның йөге бушатылды); 2. *перен. разг.* бушый төшү; эш киму, эш җиңеләю, (бераз) иркенләү; *наконец, немного разгрузились* — ниһаять, бераз иркенләдек (авыр һәм артык күп булган эштән соң әйтелә).

**РАЗГРУ'ЗКА** *ж. мн.* нет. — к. разгрузить; *разгрузка парохода* — пароходны бушату.

**РАЗГРУЗНО'Й** *спец.* — йөк бушату...-ы; йөк бушата торган; *разгрузное судно* — йөк бушата торган судно.

**РАЗГРУ'ЗОЧНЫЙ** *спец.* — йөк бушату...ы; *разгрузочный пункт* — йөк бушату пункты.

**РАЗГРЫЗА'ТЬ** *несов.* — к. разгрызть.

**РАЗГРЫЗА'ТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. разгрызться; 2. *страд.* кимерелү (мәсәлән, сөяк); ватылу (мәсәлән, чикләвек).

**РАЗГРЫ'ЗТЬ** *сов.* — 1. теш белән вату, яру; *разгрызть орех* — чикләвек вату (теш белән); *загадка не орех, не разгрызёшь* — табышмак чикләвек түгел, теш белән вата алмассың; 2. кимерү, кимереп бетерү, кимереп ташлау; *разгрызть кость* — сөяк кимерү.

**РАЗГРЫ'ЗТЬСЯ** *сов. разг.* — ватылу, ярылу (теш белән); *орех с трудом разгрызся* — чикләвек көчкә ватылды.

**РАЗГУ'Л** *м. мн* нет, *неодобр.* — 1. типтерү, эчү мәҗлесе; гыйш-гашрәт; *предаваться разгулу* — типтерүгә бирелү; 2. котырыну, котыру, шашыну, чиктән ашу; *разгул реакции* — реакциянең котырынуы.

**РАЗГУ'ЛИВАТЬ** *несов. разг.* — 1. *простореч.* к. разгулять; 2. *разг. фам.* (ял итеп, күңел ачып) йөрү, гулять итеп йөрү; тамаша (сәйран) кылып йөрү; *разгуливать по парку* — паркта күңел ачып йөрү.

**РАЗГУ'ЛИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. разгуляться, разгуливать 2.

**РАЗГУ'ЛЬЕ** *ср. мн.* нет, *разг.* — күңел ачу, кәеф-сафа; күңеллелек.

**РАЗГУ'ЛЬНЫЙ** *разг.* — 1. типтерү(челәр)...-ы; *разгульная компания* — типтерүчеләр компаниясе; 2. *устар. (жизнерадостный)* шат күңелле, көр күңелле, кәефле, артык иркен. ◇ **Вести разгульную жизнь** — гыйш-гашрәттә яшәү, кәеф-сафа сөрү, типтереп яшәү (бозык тормыш алып бару).

**РАЗГУЛЯ'ТЬ** *сов. простореч.* — юату, күңелен ачу (күтәрү); *разгулять ребёнка* — баланы юату. ◇ **Разгулять тоску** — сагышны тарату. **Разгулять сон** — йокыны ачу, йокыны качыру.

**РАЗГУЛЯ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. җәелү, кинәю; иркенәеп эш итү; *негде ему разгуляться* — аңа җәелеп (иркенәеп) эш итәргә урын юк; 2. *простореч. фам.* артык типтерү, типтерә башлау, типтерүгә бирелү; 3. *разг. фам.* (мавыгып) йокы онытылу, йокы ачылу, йокы качу; *мальчик разгулялся* — малайның йокысы ачылды; 4. аязу, ачылу; аязып (ачылып) китү; *день разгулялся* — көн аязды; 5. көчәю, котыру, котырыну; *вьюга разгулялась* — буран котырына.

**РАЗДА'БРИВАТЬ** *несов. разг.* — к. раздобрить 1.

**РАЗДА'БРИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. раздобриться.

**РАЗДАВА'ТЬ** *несов.* — к. раздать.

**РАЗДАВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. раздаться; 2. *страд.* өләшелү, бүленеп бирелү, өләшеп бирелү.

**РАЗДАВИ'ТЬ** *сов.* — 1. сыту, сытып үтерү, басып сыту, басып үтерү; *раздавить клопа* — кандаланы сыту; 2. таптау, таптату, таптап үтерү, таптап имгәтү; таптатып китү; *гусёнка раздавили* — каз бәпкәсен таптаганнар; 3. (басып) изү; яньчеп чыгару, (басып, кысып) вату; *раздавить ягоду* — җиләкне басып изү; 4. *перен. ритор.* измәсен изү, тетмәсен тетү, тармар итү; изеп ташлау; *раздавить противника* — дошманны тар-мар итү; 5. *перен. шутл.* юк итү, бетереп ташлау, тетеп салу, изеп ташлау; *раздавить взглядом* — күз карашы белән бетереп ташлау; *раздавить оппонента* — оппонентны тетеп ташлау.

**РАЗДА'ВЛИВАТЬ** *несов.* — к. раздавить.

**РАЗДА'ВЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — (басып) сытылу, изелү, ватылу; тапталу, тапталып үлү; тар-мар ителү, юк ителү.

**РАЗДА'ИВАТЬ** *несов. спец.* — к. раздоить.

**РАЗДА'ИВАТЬСЯ** *несов. спец.* — 1. к. раздоиться; 2. *страд.* күп сөт савып алыну.

**РАЗДА'ЛБЛИВАТЬ** *несов.* — к. раздолбить.

**РАЗДА'ЛБЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — чокылу, чокып киңәйтелү.

**РАЗДА'РИВАТЬ** *несов.* — к. раздарить.

**РАЗДА'РИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — бүләккә таратылу, бүләк итеп бирелү, бүләк итеп таратып бетерелү.

**РАЗДАРИ'ТЬ** *сов.* — бүләк итеп тарату, бүләк итеп бирү; бүләк итеп (таратып, өләшеп) бетерү; *он раздарил все свои вещи друзьям* — ул үзенең бар әйберсен дусларына бүләк итеп таратып бетерде.

**РАЗДА'ТОЧНЫЙ** *спец.*: **раздаточный пункт** — тарату (өләшү) пункты; **раздаточная ложка** — аш бүлә торган кашык (чүмеч).

**РАЗДА'ТЧИК** *м.*, **РАЗДА'ТЧИЦА** *ж.* — 1. таратучы, өләшүче, бүлүче, таратып торучы; 2. *спец.* йөк бирүче (тимер юлда — килгән йөкләрве махсус исемлек буенча биреп торучы кеше).

**РАЗДА'ТЬ** *сов.* — 1. тарату, таратып бирү, өләшү; өләшеп бетреү (чыгу); *раздать детям игрушки* — балаларга уен-

чыклар өләшеп чыгу; 2. бүлү, бүлеп бирү, бүлеп чыгу; *раздать роли актёрам* — актёрларга рольләр бүлеп бирү; 3. *спец.* кинәйтү, киерү, сузу; *раздать сапоги на колодке* — күн итекне калыпка салып кинәйтү.

**РАЗДА'ТЬСЯ** I *сов.* — ишетелү; ишетелеп китү; яңгырау, яңгырап китү, яңгырап ишетелү; *раздались приветственные возгласы* — тәбрикләү сүзләре яңгырады.

**РАЗДА'ТЬСЯ** II *сов.* — 1. (ике якка чигенеп, аерылып) юл бирү, юл ачу, ачык ара калдыру; *толпа раздалась* — халык чигенеп юл бирде; 2. *(расколоться, распасться)* ике якка аерылып китү, ярылып китү, ватылып таралып китү; 3. *простореч.* *(об обуви)* кинәю, сузылу, иркенәю; кинәеп китү, иркенәеп китү; 4. *простореч.* *шутл.* *(потолстеть)* калынаю, юанаю; тазарып китү.

**РАЗДА'ЧА** *ж.* — тарату, өләшү; (өләшеп, бүлеп) бирү; *раздача билетов* — билетлар өләшү.

**РАЗДВА'ИВАТЬ** *несов.* — к. раздвоить.

**РАЗДВА'ИВАТЬСЯ** *несов.* — к. раздвоиться.

**РАЗДВИГА'ТЬ** *несов.* — к. раздвинуть.

**РАЗДВИ'ГАТЬСЯ** *сов.* *простореч.* *фам.* *неодобр.* — кыймылдый (селкенә) башлау, туктаусыз кыймылдау, селкенергә тотыну; урынында тик кенә тормау (утырмау).

**РАЗДВИГА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. раздвинуться; 2. *страд.* ачып куелу; эт(әр)еп куелу; 3. (ике якка) аерыла (ачыла, озынайтыла) торган булу; *этот стол раздвигается* — бу өстәл озынайтыла.

**РАЗДВИЖНО'Й:** **раздвижной стол** — озынайтыла (кинәйтелә) торган өстәл; **раздвижные двери** — шудырмалы ишек (ике якка шудырып ачыла торган ишек).

**РАЗДВИ'НУТЬ** *сов.* — 1. як-якка эт(әр)ү; аерып кую; кинәйтү; *раздвинуть стулья* — урындыкларны аерып кую (күчереп кую); 2. ике якка аеру, аерып кую; җәю; *раздвинуть ветки* — ботакларны ике якка аеру; 3. ике якка тартып кую, тартып ачып кую; *раздвинуть занавески* — тәрәзә пәрдәләрен ике якка тартып кую; 4. *(заставить расступиться)* чигендереп араны ачу, юл ачу.

**РАЗДВИ'НУТЬСЯ** *сов.* — 1. ачылу, якякка ачылып китү; ике якка аерылу, аерылып китү; читкә этәрелү; *занавес раздвинулся* — пәрдә ачылды; *стулья раздвинулись* — урындыклар читкә этәрелделәр; 2. ике якка аерылу, чигенү; юл бирү; *толпа раздвинулась* — халык төркеме ике якка аерылды.

**РАЗДВОЕ'НИЕ** *ср.* *книж.* — 1. к. раздвоить, раздвоиться; 2. куш нәрсә, ике аерылы нәрсә; *копыто с раздвоением* — ике аерылы тояк.

**РАЗДВОЁННЫЙ** *разг.*, **РАЗДВО'ЕННЫЙ** — 1. икегә бүленгән, икегә аерылган, икегә ярылган; 2. аеры, ике аерылы, куш; *раздвоённое копыто* — аеры тояк.

**РАЗДВОИ'ТЬ** *сов.* — икегә бүлү, икегә яру, икегә аеру.

**РАЗДВОИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. икегә бүленү, икегә аерылу, тармаклану; *ручей раздвоился* — инеш икегә аерылган; 2. *перен.* икегә бүленү, ике булып күренү; *мысль раздвоилась* — фикер икегә бүленде.

**РАЗДЕВА'ЛКА** *ж.* *разг.* *фам.* — к. раздевальня.

**РАЗДЕВА'ЛЬНАЯ** *ж.* *в знач. сущ.* — чишенү бүлмәсе, кием салу бүлмәсе.

**РАЗДЕВА'ЛЬНЫЙ** *спец.* — чишенү...-ы; кием салу (элү)...-ы; *раздевальная комната* — чишенү бүлмәсе.

**РАЗДЕВА'ЛЬНЯ** *ж.* *разг.* — к. раздевальная.

**РАЗДЕВА'ЛЬЩИК** *м.*, **РАЗДЕВА'ЛЬЩИЦА** *ж.* *разг.* — гардеробчы (чишенү бүлмәсендә өс киемнәрен алып һәм биреп торучы кеше).

**РАЗДЕВА'ТЬ** *несов.* — к. раздеть.

**РАЗДЕВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. раздеться; 2. *страд.* чишендерелү, киеме салдырылу; чишендереп алыну, салдырып алыну.

**РАЗДЕ'Л** *м.* — 1. *только ед.* к. разделить 1, 2, 3; *раздел поля* — кырларны бүлү (бүлеп чыгу); *раздел имущества* — милекне бүлешү; *раздел мировых рынков* — дөнья базарларын бүлү (империалистик илләрнең бүлүе); 2. аерым яшәү; *жить в разделе* — аерым яшәү, башка чыгып яшәү; 3. бүлек, бүлем; кисәк, өлеш; *книга состоит из четырех разделов* — китап дүрт бүлектән тора; 4. сырт, субүләр; чик.

**РАЗДЕ'ЛАТЬ** *сов.* — 1. *спец.* *(обработать)* эшкәртү, эшкәртеп кую, эшкәртеп хәзерләп кую; *разделать грядки* — түтәлләрне эшкәртеп хәзерләп кую; 2. *спец.* кинәйтү, зурайту; *разделать дыру* — тишекне зурайту; 3. *простореч.* *(отделать)* бизәкләү, нәкышьләү; 4. *перен.* *разг.* сүгеп ташлау, орышу, пешерү, акылга өйрәтү, кирәген бирү; кыйнап (тәпәләп) ташлау. ◇ **Разделать кого-нибудь под орех** — к. орех. **Разделать шкаф под дуб** — шкафны имән төсенә кертеп буяп эшләү. **Разделать печную трубу** — морҗаны тышлау (морҗа чыгарганда, янгын чыкмасын өчен, түшәм һәм морҗа арасына кирпеч катлавы куеп калдыру. **Разделать рыбу** — балыкны ярып чистарту. **Разделать тушу** — түшкәне чабу.

**РАЗДЕ'ЛАТЬСЯ** *сов.* *разг.* — 1. *фам.* исәпне өзү, исәп-хисапны өзү, алыш-бирешне туктату; *разделаться с кредиторами* — кредиторлар белән исәпне өзү; 2. *перен.* котылу, буша(н)у, өзелешү; *разделаться с долгами* — бурычлардан котылу; 3. *перен.* исәп-хисапны өзү, үч алу, үч кайтару; кирәген бирү, акылга өйрәтү, арт сабагын укыту; *я разделаюсь с ним* — мин аны акылга өйрәтермен әле (ягъни үчемне алырмын).

**РАЗДЕЛЕ'НИЕ** *ср.* *книж.* — 1. к. разделить, разделиться; 2. бүленеш; *разделение труда* — хезмәт бүленеше. ◇ **По разделениям** *воен.* *спорт.* — бүлеп-бүлеп, һәрберсен аерым-аерым (мәсәлән, гимнастика күнегүләре ясаганда). **Разделение церквей** *ист. ор.* — католик һәм православие чиркәүләренең бер-берсеннән аерылуы.

**РАЗДЕЛИ'МЫЙ** *книж.* — бүленүче, бүленмәле; бүленә (аерыла) торган; бүләргә (аерырга) мөмкин булган.

**РАЗДЕЛИ'ТЕЛЬ** *м.* — бүлгеч, аергыч (мәсәлән, каталог ящикларындагы карточкаларны аерып тору өчен).

**РАЗДЕЛИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. *книж.* бүлеп (аерып) тора торган; аеручы; чик...-ы; *разделительная черта* — чик сызыгы; 2. *грам.* бүлүче, бүлем...-ы; *разделительный союз* — бүлүче теркәгеч; *разделительное числительное* — бүлем саны. ◇ **Разделительное суждение** *филос.* — аеру хөкеме (ике яки берничә фикердән, мөмкинлектән берсен сайлап алуны белдергән хөкемләү).

**РАЗДЕЛИ'ТЬ** *сов.* — 1. бүлү, аеру, бүлеп чыгу; *разделить десять на пять* — унны бишкә бүлү; *разделить область на районы* — өлкәне районнарга бүлү; *разделить книгу на главы* — китапны бүлекләргә бүлеп чыгу; 2. бүлеп бирү, өләшү, бүлешү; *разделить наследство* — мирасны бүлеп бирү; 3. *перен.* аеру, тарату; 4. *перен.* аерып тору, чикләп тору; *река разделила эти области* — бу өлкәләрне елга аерып тора; 6. *перен. книж.* (ике төркемгә) аеру; *этот вопрос разделил собрание на две группы* — бу мәсьәлә җыелышны ике төркемгә аерды; 7. *перен.* бүлешү, уртаклашу, бергә кичерү; *я разделю с ним последний кусок хлеба* — мин аның белән соңгы сынык икмәгемне бүлешергә әзер; 8. *перен. книж.* кушылу, ризалашу, килешү; куәтләү; уртаклашу, бер карашта тору, уртак булу (фикерләр); *разделить чьё-н. мнение* — берәүнең фикеренә кушылу. ◇ **Разделить чью-н. любовь** — мәхәббәткә мәхәббәт белән җавап бирү.

**РАЗДЕЛИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. бүленү, аерылу, аерылып китү; *отряд разделился на три группы* — отряд өч төркемгә бүленде; 2. бүленешү, аерылып чыгу, башка чыгу; *дети после смерти отца разделились* — аталары үлгәч, балалар башка чыктылар. ◇ **Наши обязанности разделились** — безнең вазифалар аерып билгеләнде.

**РАЗДЕ'ЛКА** *ж. спец. разг.* — 1. к. разделать; 2. *спец.* кирпеч катлавы (мәсәлән, морҗаны түшәм һәм түбә аша үткәргәндә, янгын чыкмаслык итеп, аралыкка салып калдырылган кирпечләр); 3. *спец.* эшкәртелеш, эшләнеш; бизәлеш, буялыш; эшләнү (эшкәртелү) сыйфаты; *разделка мебели отличалась тщательностью* — мебельнең эшләнеше бик шәп иде.

**РАЗДЕ'ЛОЧНЫЙ** *спец.* — эшкәртү...-ы; *разделочные работы* — эшкәртү эшләре (чистарту, нәкышьләү, бизәү һ. б.).

**РАЗДЕ'ЛЫВАТЬ** *несов.* — 1. к. разделать; 2. (әллә ниләр) эшләү, ясап күрсәтү, кыландыру, маташтыру; *разделывать всякие фокусы* — әллә нинди төрле фокуслар ясап күрсәтү; 3. *простореч. фам.* әшәкеләнү, әшәке кылану.

**РАЗДЕ'ЛЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг.* к. разделаться; 2. *страд.* эшкәртелү, бизәлү, нәкышьләнү; чистартылу, киңәйтелү, зурайтылу.

**РАЗДЕ'ЛЬНО** *нареч.* — 1. аерым, аерым-аерым; башка чыгып; *жить раздельно* — аерым яшәү; 2. аерып-аерып, ачык итеп, аңлаешлы итеп; *произнести что-н. раздельно* — аерып-аерып әйтү.

**РАЗДЕЛЬНОКОПЫ'ТНЫЕ** *зоол.* — аеры тояклылар.

**РАЗДЕЛЬНОЛЕПЕ'СТНЫЙ** *бот.* — аеры яфракчыклы; *раздельнолепестный венчик* — аеры яфракчыклы таҗ (чәчәктә).

**РАЗДЕЛЬНОПО'ЛОСТЬ** *ж. мн.* нет, *биол.* — аерым җенеслелек.

**РАЗДЕЛЬНОПО'ЛЫЕ** *биол.* — аерым җенесләр.

**РАЗДЕЛЬНОПО'ЛЫЙ** *биол.* — аерым җенесле (аталык җенесе бер үсемлектә, аналык җенесе икенче үсемлектә булган).

**РАЗДЕ'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. бүленгәнлек, аерымлык; 2. ачыклык, анык-лык; аермачык булу.

**РАЗДЕ'ЛЬНЫЙ** — 1. *офиц.* аерым, мөстәкыйль; 2. *с.-х* аеры; *раздельная уборка хлебов* — игеннәрне аеры урып-җыю; 3. аермачык, ачык; аңларлык итеп...; *раздельное произношение* — (сүзне, җөмләне) аермачык әйтү. ◇ **Раздельный акт** *право* — бүленешү турындагы акт.

**РАЗДЕЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. разделить.

**РАЗДЕЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — к. разделиться; *звуки разделяются на гласные и согласные* — авазлар сузыкларга һәм тартыкларга бүленәләр.

**РАЗДЁРГАТЬ** *сов. разг.* — (чүпрәктән җепне) йолкып бетерү, суырып бетерү, җепселләргә аерып бетерү.

**РАЗДЁРГИВАТЬ** *несов. разг.* — 1. к. раздёргать; 2. к. раздёрнуть.

**РАЗДЁРГИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. раздёрнуться; 2. *страд.* йолкыну, тартып чыгарылу, суырылу (мәс., чүпрәкнең җепләргә аерылуы); 3. *страд.* тартып (ачып) куелу.

**РАЗДЁРНУТЬ** *сов. разг.* — тарту, тартып кую, тартып ачу; тартып ачып җибәрү; *раздёрнуть занавески* — пәрдәне тартып ачып җибәрү.

**РАЗДЁРНУ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — ике якка ачылып китү, тартылып ачылып китү; *занавес раздёрнулся* — пәрдә ике якка ачылып китте.

**РАЗДЕ'ТЫЙ** — 1. чишендерелгән, киеме салдырылган; 2. *(ограбленный)* киеме салдырып алынган, киеме таланган; 3. *разг.* ялангач, чишенгән.

**РАЗДЕ'ТЬ** *сов.* — 1. чишендерү, өстен (киемен) салдыру, чишендереп ташлау; *раздеть ребёнка* — баланы чишендерү; 2. *разг.* өстен ачу, өстен ачып ташлау (йоклаганда); 3. *разг.* чишендерү, талау.

**РАЗДЕ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. чишенү, киемен салу, өстен салу; 2. өстен ачып ташлау, алып ташлау (юрганын һ. б.).

**РАЗДИРА'ТЕЛЬНЫЙ** — күңелгә авыр, газаплы, ачындыргыч; җан әрнеткеч, йөрәк өзгеч; күңелне борчый (газаплый, изалый) торган.

**РАЗДИРА'ТЬ** *несов.* — 1. *разг.* к. разодрать; 2. *перен. книж.* эчтән таркату, эчтән җимерү, эчтән телгәләү; 3. *книж.* (*тер-*

*зать)* (йөрәкне) газаплау, җәфалау, изалау, телгәләү; күңелне әрнетү, ачындыру.

**РАЗДИРА'ТЬСЯ** *несов.*—1. к. разодраться 1, 2; 2. *страд. книж.* өзәләнү, ачыну, әрнү; 3. эчтән телгәләнү, таркалу, җимерелү.

**РАЗДИРА'ЮЩИЙ** — үзәк (йөрәк) өзгеч, җан әрнеткеч, ачы; коточкыч, авыр; *раздирающий душу крик* — йөрәк өзгеч тавыш; *раздирающие сцены* — коточкыч күренешләр.

**РАЗДОБРЕ'ТЬ** *сов. разг. фам.*— тазарып китү, тулыланып китү; симереп китү, юанаеп китү.

**РАЗДО'БРИТЬ** *сов.*—1. *разг.* юмартландыру, шәфкатьле итү; күңелен йомшарту; 2. *простореч.* (берәр нәрсә кушып) сыйфатын яхшырту (мәсәлән, камыр ашларга сөт, май, йомырка кебек нәрсәләр кушып тәм кертү).

**РАЗДО'БРИТЬСЯ** *сов. разг.*— юмартлану, юмартланып китү; шәфкать күрсәтү, шәфкатьләнәнеп китү, күңеле йомшарып китү.

**РАЗДОБРЯ'ТЬ** *несов. простореч.*— к. раздобрить 2.

**РАЗДОБЫВА'ТЬ** *несов. разг.*— к. раздобыть.

**РАЗДОБЫВА'ТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— булдырылу, табылу, кулга төшерелү.

**РАЗДОБЫ'ТЬ** *сов. разг.*— табу, табып алу; эзләп табу, кулга төшерү; *раздобыть нужную книгу* — кирәкле китапны табып алу.

**РАЗДОИ'ТЬ** *сов. спец.*— сөтен арттыру, сөт бирешен (савымын) арттыру.

**РАЗДОИ'ТЬСЯ** *сов. спец.*— сөте арту, сөте күбәю, күп сөт бирә башлау, савымы арту.

**РАЗДО'Й** *м. спец.*—1. к. раздоить; 2. сөт саву, сыер саву.

**РАЗДОЛБИ'ТЬ** *сов.*— чокып киңәйтү, зурайтү (мәс., өтерге белән); *раздолбить отверстие* — тишекне чокып киңәйтү.

**РАЗДО'ЛЬЕ** *ср. мн.* нет —1. киңлекләр, иркенлекләр; киң сахра; *раздолье колхозных полей* — колхоз кыры киңлекләре; 2. *перен. разг.* иркенлек, иркен тормыш; үз иркендә (ихтыярында) булу, үзе теләгәнчә эш итү; *ему теперь раздолье* — ул хәзер үз иркендә. ◇ **По широкому раздолью моря** — иксез-чиксез диңгез кочагында.

**РАЗДО'ЛЬНЫЙ** *обл. поэт.*— киң, мул, бай, иркен, ирекле; *раздольная жизнь* — иркен тормыш.

**РАЗДО'Р** *м.*—1. ызгыш, талаш, җәнҗал, гауга; тынышмау; *семейные раздоры* — семья җәнҗаллары; 2. килешмәүчәнлек, дошманлык, дошман күрү, низаг; *сеять раздоры* — дошманлык тарату; 3. чуалыш, болганыш, үзара сугыш; *раздоры удельных князей* — удел князьләренең үзара сугышулары. ◇ **Яблоко раздора** — көнчелек, (ызгыш) алмасы (ызгыш-талаш сәбәпчесе). **Жить в раздоре** — этле-мәчеле тору.

**РАЗДОРО'ЖЬЕ** *ср. обл.*— к. распутье.

**РАЗДОСА'ДОВАТЬ** *сов. разг.* — ачуландыру, ачуын китерү, кәефен кыру, хәтерен калдыру, үкевдерү, ачындыру.

**РАЗДОСА'ДОВАТЬСЯ** *сов. разг. фам.*— кәеф кырылу, ачу килү; хәтер калу, үкенү, ачыну, хурлану.

**РАЗДРАЖА'ТЬ** *несов.*— к. раздражить.

**РАЗДРАЖА'ТЬСЯ** *несов.*—1. к. раздражиться; 2. *страд. физиол.* ярсытылу, тынычсызландырылу (мәс., нерв очлары).

**РАЗДРАЖЕ'НИЕ** *ср. книж.*—1. к. раздражить; 2. ялкынсыну, кызару, пешегү; *раздражение кожи* — тиренең кызаруы; 3. *только ед.* ачу, ярсу, кызу, ризасызлык.

**РАЗДРАЖЁННО** *нареч.*— кызып, ачуланып, ярсып, тынычсызланып, ачу белән.

**РАЗДРАЖЁННЫЙ** — 1. ярсы(тыл)ган, кызган, ачуы килгән; 2. ачулы, ярсулы; *раздражённый голос* — ярсулы тавыш; 3. ялкынсынган, кызарган, пешеккән; *раздражённая кожа* — кызарган тире.

**РАЗДРАЖИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— тынычсызланучанлык, ярсучанлык.

**РАЗДРАЖИ'МЫЙ** *книж.*— ярсучан, тынычсызланучан, тәэсирләнә торган, тәэсиргә бирелүчән.

**РАЗДРАЖИ'ТЕЛЬ** *м. физиол.*— ярсытучы, тынычсызлаучы, ярсыткыч; *внешний раздражитель* — тышкы ярсыткыч.

**РАЗДРАЖИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — ярсучанлык, тынычсызланучанлык; тиз ярсучан (кызып китүчән, ачуланучан) булу.

**РАЗДРАЖИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. тиз ачуланучан, кызып (кабынып, ярсып) китүчән; ярсучан, кызучан; *раздражительный человек* — бик тиз кабынып китүчән кеше; 2. *устар. (возбуждающий)* канны уйната торган, кыздыра торган.

**РАЗДРАЖИ'ТЬ** *сов.*—1. ачуландыру, ачуын китерү, ачуын кабарту, ачуын кузгату; канын кыздыру, канын бозу, борчу, ярсыту; *раздражить неуместными шутками* — урынсыз шаяртулар белән ачуын китерү; 2. *физиол.* ярсыту, тынычсызландыру; *раздражить нервные окончания* — нерв очларын тынычсызландыру; 3. *(вызвать боль, зуд, воспаление)* кычыттыру, ачыттыру; ялкынсындыру, кызарту, тынычсызлау; 4. кузгатып (көчәйтеп) җибәрү; *раздражить аппетит* — ашыйсы килүне кузгатып җибәрү.

**РАЗДРАЖИ'ТЬСЯ** *сов.*—1. ачу килү, кызу, кызып китү, ярсу; *раздражиться и сказать резкость* — кызып китеп каты сүз әйтеп ташлау; 2. ялкынсыну, кызару, пешегү, бозылу; *кожа раздражилась* — тире ялкынсынган.

**РАЗДРА'ЗНИВАТЬ** *несов. разг.*— к. раздразнить.

**РАЗДРА'ЗНИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— 1. үчекләп ярсытылу, үртәп ачуландырылу; 2. көчәйтеп, кузгатып җибәрелү (мәсәлән, ашыйсы килү).

**РАЗДРАЗНИ'ТЬ** *сов. разг.*—1. үртәп ачуландыру, үчекләп ачуын китерү, үртәп ярсыту; котырту; *раздразнить человека* — кешене үртәп ачуландыру; 2. *перен.* уяту, кузгату, кузгатып җибәрү; *раздразнить аппетит* — аппетитны кузгату.

**РАЗДРОБИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— ваклана торган булу, ватылучанлык, бүленүчәнлек, таркалучанлык.

**РАЗДРОБИ'МЫЙ** *книж.*— ваклана торган, ватыла торган, ватылучан, таркалучан.

**РАЗДРОБИ'ТЕЛЬНЫЙ** *спец.*— ваклау...-ы; ваклагыч, ваклый торган, вата торган; *раздробительный аппарат* — (таш һ. б.) ваклый торган аппарат.

**РАЗДРОБИ'ТЬ** *сов.* — 1. ваклау, ватып бетерү, вак кисәкләргә вату; *раздробить камень* —ташны ваклау; 2. *мат.* әйләндерү, күчереп исәпләү, әйләндереп исәпләү; *раздробить метры в сантиметры* — метрны сантиметрларга әйләндерү.

**РАЗДРОБИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. ваклану, вак кисәкләргә ватылу, ватылып бетү, ватланып бетү; 2. *мат.* (зур берәмлектән кечкенәгә) әйләндереп исәпләнелү, күчереп исәпләнелү (мәс., метрдан сантиметрларга).

**РАЗДРОБЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — к. раздробить.

**РАЗДРОБЛЁННОСТЬ** *разг.*, **РАЗДРО'БЛЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— вакланганлык, вак кисәкләргә бүлгәләнгәнлек; таркаулык.

**РАЗДРОБЛЁННЫЙ, РАЗДРО'БЛЕННЫЙ** — 1. вакланган, вак кисәкләргә ватылган; *раздроблённый камень*—вакланган таш; 2. чәрдәкләнгән; *ему ампутировали раздрбб́ленную руку* (Шолохов) — аның сөякләре чәрдәкләнгән кулын кистеләр; 3. *перен.* вак, таркау (аерым хуҗалыкларга бүлгәләнгән); *раздрбб́ленные крестьянские хозяйства*—таркау крестьян хуҗалыклары.

**РАЗДРОБЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. раздробить.

**РАЗДРОБЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — к. раздробиться.

**РАЗДРУЖИ'ТЬ** *сов. разг.* — дуслыкны өзү, дошманлаштыру, аралары бозу, дусларны әчелешле итү.

**РАЗДРУЖИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — дуслык бетү, ара өзелү, ара бозылу; бозылышу, әчелешле булу.

**РАЗДУВА'ЛЬНЫЙ** *спец.*— һава өрдерә торган, өрдергеч; *раздувальный мех* — һава өрдерә торган күрек.

**РАЗДУВА'ТЬ** *несов.* — 1. к. раздуть; 2. *разг. (развевать)* җилбердәтү, җилфердәтү; (җил) кабарту.

**РАЗДУВА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. раздуться; 2. *страд.* кабызылу, яндырылу; дөрләтеп җибәрелү (мәсәлән, ут, учак); 3. *страд. перен.* күпертелү, арттырып күрсәтелү (мәсәлән, мәгълүматлар); артык киңәйтелү (мәсәлән, штатлар); 4. *страд.* таратылу, туздырылу, тузгытылу, очыртылу (мәсәлән, тузан һ. б.).

**РАЗДУ'МАТЬ** *сов.*— кире уйлау, уйлаган уеннан (фикереннән, ниятеннән) кире кайту; фикерне (ниятне) үзгәртү; башкача уйлау,...-маска булу; *я раздумал ему писать* — мин аңа хат язмаска булдым.

**РАЗДУ'МАТЬСЯ** *сов. разг. фам.*— уйлану, уйлана башлау, уйга чуму, уйга бату, уйга калу, уйланып тору (утыру); *раздумался о своих делах* — үзенең эшләре турында уйлана башлады.

**РАЗДУ'МЧИВО** *нареч.*— уйлап, уйлап кына; чамалап кына, үлчәп кенә; *он говорит не торопясь, раздумчиво* — ул ашыкмыйча, уйлап кына сөйли.

**РАЗДУ'МЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.*— уйчанлык, күп уйлануччанлык, (артык) уйлап эш итүчәнлек; икеләнүчәнлек. тәвәккәлсезлек.

**РАЗДУ'МЧИВЫЙ** *разг.*— уйчан, күп уйланучан, уйлап (чамалап, үлчәп) эш итүчән; икеләнүчән, тәвәккәл булмаган.

**РАЗДУ'МЫВАТЬ** *несов.*— 1. к. раздумать; 2. уйлау, уйлану, уйланып тору; уйга калу; *раздумывать о будущем* — киләчәк турында уйлану; 3. *разг.* (озын-озак) уйлап тору, икеләнеп тору; *раздумываю, купить или нет* — алыргамы, юкмы дип уйлап (икеләнеп) торам.

**РАЗДУ'МЫВАТЬСЯ** *несов. разг. фам.*— к. раздуматься.

**РАЗДУ'МЬЕ** *ср. мн.* нет — уй, уйлану, уйланып тору; *погрузиться в раздумье* — уйга бату. ◇ **Его взяло раздумье** — ул уйга калды (ягъни икеләнеп, аптырап калды).

**РАЗДУРА'ЧИТЬСЯ** *сов. просторeч.*— артык шаяру, азыну, ахмаклану; артык юләрләнеп (шаярып, котырып) китү.

**РАЗДУРИ'ТЬСЯ** *сов. просторeч. неодобр.*— к. раздурачиться.

**РАЗДУ'ТИЕ** *ср. мн.* нет, *спец.*— к. раздуть, раздуться.

**РАЗДУ'ТОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг. неодобр.*— күпертелгәнлек, арттырып күрсәтелгәнлек; күпертелү, арттырылу, артык киңәйтелү; *раздутость цифр* — саннарның (мәгълүматларның) арттырып бирелгән булуы.

**РАЗДУ'ТЫЙ** — 1. өрелгән, өреп кабартылган, өреп тутырылган; 2. кабарган күбенгән, күпкән, шешкән, шешенгән; *раздутая щека* — шешкән яңак; 3. *перен. разг. неодобр.* күпертелгән, арттырылган, арттырып күрсәтелгән, артык киңәйтелгән; *раздутые цифры* — арттырып күрсәтелгән саннар.

**РАЗДУ'ТЬ** *сов.*— 1. (өреп) кабызу, яндыру, дөрләтү, дөрләтеп җибәрү; *раздуть огонь* —утны өреп дөрләтеп җибәрү; 2. *перен. разг.* кабызу, кабызып җибәрү; *не дадим агрессорам раздуть пожар новой войны* — агрессорларга яңа сугыш уты кабызып җибәрергә юл куймабыз; 3. *перен. безл. просторeч.* кабару, күбү, күбенеп чыгу; шешү, шешеп чыгу; *щеку раздуло* — яңагы шешеп чыкты; 4. кабарту; өреп кабарту, өреп һава тутыру; *ветер раздул паруса* — җил җилкәннәрне кабартты; 5. *перен.* күпертү, арттыру; күпертеп (арттырып) күрсәтү; артык киңәйтү; *раздуть успех* — уңышны күпертеп күрсәтү; 6. *разг.* тарату, туздыру; очырту, очыртып китү; *ветер раздул летучки одуванчика* — җил тузганак йончаларын очыртты.

**РАЗДУ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. кабару, күбенү; кабарыну, шешенү; кабарып (шешеп) чыгу; *щека раздулась* — яңагы шешеп чыккан; 2. һава тулу, кабару, өрелү; *пузырь раздул-*

*ся* — куык кабарды; 3. *разг. шутл.* тулыланып китү, юанаеп китү, тазарып китү.

**РАЗДУШИ'ТЬ** *сов. разг.*—(күп итеп) хушбуй сөртү; ислемай сибү, ислемай бөркү (сиптерү); *раздушить платок* — кулъяулыкка ислемай бөркү.

**РАЗДУШИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*—(күп итеп) ислемай сөртенү, хушбуй сибү (үзенә).

**РАЗЕВА'ТЬ** *несов. разг.*— к. разинуть.

**РАЗЕВА'ТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— киереп ачылу, киң ачылу (авыз).

**РАЗЖА'ЛОБИТЬ** *сов.*— кызгандыру, жәлләтү; күңелен йомшарту (эретү).

**РАЗЖА'ЛОБИТЬСЯ** *сов. разг.*— кызгану, жәлләү, күңел йомша(р)у, шәфкате килү.

**РАЗЖА'ЛОВАНИЕ** *ср. мн.* нет, *дорев ол.*— к. разжаловать 1.

**РАЗЖА'ЛОВАННЫЙ** — 1. (дәрәҗәсе) төшерелгән, түбәнәйтелгән; чины алынган 2; *в знач. сущ. м. устар.* дәрәҗәсе алынган гаскәри.

**РАЗЖА'ЛОВАТЬ** *сов. офиц.*— 1. дәрәҗәсен төшерү, дәрәҗәсен (чинын) түбәнәйтү яки алу; *разжаловать офицера в рядовые* — офицерны рядовойлыкка төшерү (солдатка әйләндерү); 2. *перен. устар. шутл.* ышанычтан мәхрүм итү; шәфкатьтән мәхрүм итү.

**РАЗЖА'ТЬ** *сов.*— 1. (йомылганны) ачу, ачып җибәрү; җәю, җәеп жибәрү; *разжать кулак* — йодрыкны ачу; 2. язу, язып җибәрү, язып турайту; *разжать пружину* — пружинаны язып турайту; 3. аеру, аерып чыгару; *разжать что-н. клином* — бер нәрсәне чөй сугып аеру; 4. *безл. просторeч.* зураю, киңәю, киңәеп китү; *от теплоты предметы разжало* — җылыдан әйберләр киңәеп киткән.

**РАЗЖА'ТЬСЯ** *сов.*— ачылу; җәелү, язылу; ачылып (җәелеп) китү; язылып тураю, язылып китү; *пружина разжалась* — пружина язылып китте.

**РАЗЖЕВА'ТЬ** *сов.*— 1. яхшылап чәйнәү, чәйнәп бетерү; чәйнәп ваклау; *разжевать пищу* — азыкны яхшылап чәйнәү; 2. *перен. разг. фам.* чәйнәп бирү, чәйнәп каптыру, җентекләп аңлату, төшендереп бирү; *каждую мысль ему нужно разжевать* — аңа һәрбер фикерне чәйнәп бирергә кирәк; 3. *перен. просторeч. шутл.* (яхшылап, төрле яктан) уйлап карау, уйлап аңлау, төшенү; *это дело надо разжевать* — бу эшне яхшылап уйлап карарга кирәк әле.

**РАЗЖЕВА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— яхшылап чәйнәлү; чәйнәп ваклану.

**РАЗЖЁВЫВАТЬ** *несов.*— к. разжевать.

**РАЗЖЁВЫВАТЬСЯ** *несов. разг.*— к. разжеваться.

**РАЗЖЕНИ'ТЬ** *сов. просторeч. фам.*— хатынын аерту, ир белән хатынны аерту.

**РАЗЖЕНИ'ТЬСЯ** *сов. просторeч. фам.*— хатынын аеру, хатыны белән аерылышу.

**РАЗЖЕ'ЧЬ** *сов.*— 1. ягып җибәрү; кабызу, кабызып (яндырып) җибәрү; көйрәтеп (дөрләтеп) җибәрү; *разжечь огонь* — ут ягып җибәрү; 2. кыздыру, кыздырып җиткерү; *разжечь железо для ковки* — чүкү өчен тимерне кыздырып җиткерү; 3. *безл.* кызу; *песок жаром разожгло* — эсседән ком кызган; 4. *перен.* кабызу, кыздыру, көчәйтү, җәелдерү; кыздырып (кузгатып) җибәрү; *капиталисты стараются разжечь национальную вражду* — капиталистлар милли дошманлыкны кабызырга тырышалар.

**РАЗЖЕ'ЧЬСЯ** *сов.*— 1. янып (кабынып, дөрләп) китү; дөрләп яна башлау; *дрова разожглись* — утыннар янып китте; 2. *перен. книж.* кызу, көчәю, җәелү; кузгалу, уяну; кабынып китү; кызып (көчәеп) китү; *вражда разожглась* — дошманлык кызып китте.

**РАЗЖИ'ВА** *ж. мн.* нет, *просторeч.*— 1. (*пожива*) табыш, файда; көтелмәгән мал (килер); *получил разживу* — кулга көтелмәгән мал керде; 2. *разг.* к. разжиться.

**РАЗЖИВА'ТЬСЯ** *несов разг.*— к. разжиться.

**РАЗЖИ'Г** *м. мн.* нет, *спец.*— к. разжечь 1, 2; *разжиг угля* — күмер яндыру.

**РАЗЖИГА'ТЬ** *несов.*— к. разжечь.

**РАЗЖИГА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. разжечься; 2. *страд.* яндырылу, кабызылу; 3. *страд. перен.* көчәйтелү, җәелдерелү, кыздырылу, кузгатылу; кыздырып, кабызып җибәрелү (мәсәлән, бәхәс, дәрт, дошманлык һ. б. ш.).

**РАЗЖИДИ'ТЕЛЬ** *м. тех.*— сыеклагыч, сыеклаткыч, сыекландыргыч (лак, буяу һ. б. ларга кушып аларны сыеклау өчен хезмәт итә торган сыекчалар).

**РАЗЖИДИ'ТЬ** *сов.*— сыеклау, сыекландыру, сыегайту; сыегайтып җибәрү, сыеграк итү, су кушу; *разжидить краску* — буяуны сыегайту; *разжидить молоко* — сөткә су кушу.

**РАЗЖИДИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— сыеклану, сыегаю; сыекланып (сыегаеп) китү.

**РАЗЖИЖА'ТЬ** *несов.*— к. разжидить.

**РАЗЖИЖА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. *разг.* к. разжидиться; 2. *страд.* сыекландырылу, сыегайтылу, су кушылу.

**РАЗЖИЖЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж. спец.*— к. разжидить, разжижаться.

**РАЗЖИЖИ'ТЕЛЬ** *м.*— к. разжидитель.

**РАЗЖИМА'ТЬ** *несов.*— к. разжать.

**РАЗЖИМА'ТЬСЯ** *несов.*— к. разжаться.

**РАЗЖИ'МНЫЙ** *спец.*— 1. (*такой, что разжимается*) ачылмалы, язылмалы; ачыла (языла) торган; 2. ача торган, яза торган, турайта торган; турайткыч...; *разжимное приспособление* — турайткыч җайланма.

**РАЗЖИРЕ'ЛОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.*— артык симезлек, артык симергәнлек; бик көр(әйгән) булу.

**РАЗЖИРЕ'ЛЫЙ** *разг.*— бик симез, артык көр; артык симергән, май баскан.

**РАЗЖИРЕ'ТЬ** *сов. разг.*— артык симерү, симереп китү; бик көрәю, май басу, артык тазару.

**РАЗЖИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. (*разбогатеть*), баю, баеп китү, баеп бетү; (*нажиться*) байлык арттыру, күп табыш (файда) алу; 2. *просторeч.* табу, табып алу, булдыру, юнәтү; *разжиться деньгами* — акча табу.

**РАЗЖУЖЖА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— бик нык безелли (жуылдый) башлау.

**РАЗЗАВО'Д** *м. мн.* нет, *разг.*: **на раззавод** — үрчетү өчен; **купила курочку с петушком на раззавод** — үрчетү өчен тавык белән этәч сатып алдым.

**РАЗЗАДО'РИВАТЬ** *несов. разг.*— к. раззадорить.

**РАЗЗАДО'РИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— 1. к. раззадориться; 2. *страд.* ярсытылу, кыздырылу, котыртылу; дәртләндерелү, гайрәтләндерелү.

**РАЗЗАДО'РИТЬ** *сов. разг.*— (котыртып) гайрәтләндерү, ярсыту, кыздыру; ялкынландыру, җилкендерү; кызыктыру, дәртләндерү.

**РАЗЗАДО'РИТЬСЯ** *сов. разг.*— гайрәтләнеп (ялкынланып) китү, дәртләнеп (җилкенеп) китү; ярсу, кызу, котыру.

**РАЗЗВА'НИВАТЬ** *несов. разг. фам.*— к. раззвонить.

**РАЗЗВА'НИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— к. раззвониться.

**РАЗЗВОНИ'ТЬ** *сов. простореч. неодобр.*— хәбәр (сүз, гайбәт) тарату; бөтен кешегә фаш итү.

**РАЗЗВОНИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. артык озак чаң сугу, туктаусыз чаң кагу; туктаусыз шалтырату; 2. *фам. неодобр.* күп сөйләнү, юк-барны сөйләп ташлау, гайбәт сату.

**РАЗЗЕ́ВА** *м.* и *ж.*— к. разиня.

**РАЗЗЕВА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. *(начать усиленно зевать)* авыз киереп иснәү, исни башлау; 2. *перен. простореч. неодобр.* авыз ачып карану, карап тору; 3. *перен. простореч. неодобр. (начать невнимательно работать)* күңел бирми (игътибарсыз) эшли башлау.

**РАЗЗНАКО'МИТЬ** *сов. разг.*— дуслыкны өзү, ара бозу; *раззнакомить друзей сплетнями* — гайбәт белән дусларның арасын бозу.

**РАЗЗНАКО'МИТЬСЯ** *сов. разг.*— танышлыкны бетерү, танышлыкны өзү; дуслыкны бетерү, дуслыкны өзү; ара бозылу; ташлашу.

**РАЗЗНАКО'МЛИВАТЬ** *несов.*— к. раззнакомить.

**РАЗЗНАКО'МЛИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— к. раззнакомиться.

**РАЗЗОЛА'ЧИВАТЬ** *несов. разг.*— к. раззолотить.

**РАЗЗОЛА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— алтынга манылу.

**РАЗЗОЛОТИ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. алтынлау, алтынлап чыгу, алтынга ману, алтын йөгертү, алтын белән каплау; *раззолотить статую* — һәйкәлне алтын белән каплау; 2. *спец.* (читләренә) алтын җеп тотып чыгу, алтын ука белән чигү.

**РАЗЗОЛО'ЧЕННЫЙ** *разг.*— 1. алтынлы, алтын путаллы; алтын укалы; *раззолоченные одежды* — алтын укалы киемнәр; 2. алтынланган, алтын (суы) йөгертелгән, алтынга манылган, алтын белән капланган.

**РАЗЗУДЕ'ТЬСЯ** *сов. простореч.*— 1. бик нык кычыта (кымыржый, әрни) башлау, сулкылдап сызлый башлау; *больное плечо раззуделось* — авыру җилкәм сулкылдап сызлый башлады; 2. *перен.* (эшләргә) кул кычыту, кызып (кымыржып) тору; 3. чаж-чож килү, чыжылдый башлау, чыжылдарга тотыну; *коса раззуделась* — чалгы чыжылдый башлады.

**РАЗЗУДИ'ТЬ** *сов. простореч.*— кычыттырып җибәрү, кымыржытып җибәрү; сызлауны (әрнүне, кычытуны) кузгатып җибәрү.

**РАЗЗУ'ЖИВАТЬ** *несов. простореч.*— к. раззудить.

**РАЗЗУ'ЖИВАТЬСЯ** *несов. простореч.*— к. раззудеться.

**РАЗЗЯ'ВА** *м.* и *ж. простореч. пренебр.*— к. разиня.

**РАЗИ'НУТЬ** *сов. разг.*— (авызны киң итеп) ачу, киереп ачу. ◇ **Стоит, разинув рот** — авызын ачып карап тора, авызы белән кош тота. **Разиня** (или **разинув**) **рот** *разг. фам. перен.*— 1. әһәмият бирмичә, игътибарсыз, салкын карап; *работать, разиня рот* — игътибарсыз эшләү; 2. авыз ачып, исе китеп, шаккатып, таң калып; *все слушали его, разинув рты* — барысы да авызларын ачып аны тыңлыйлар иде.

**РАЗИ'НЯ** *м.* и *ж. пренебр.*— ачык авыз; булмаган, пешмәгән, җебегән (кеше турында).

**РАЗИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— искиткеч булу.

**РАЗИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.*— искиткеч, искитәрлек, гаҗәеп, гаҗәп, шәп, хәйран калырлык, таңга калдырырлык; тәэсирле, гыйбрәтле; *разительные перемены* — хәйран калырлык үзгәрешләр.

**РАЗИ'ТЬ** I *несов. книж.*— 1. сугу, бәрү, ору, кундыру; сугып егу; 2. җиңү, кыру, кырып салу; чабу, кисү, турау; *разить врагов* — дошманнарны кыру; 3. *(изумлять)* гаҗәпләндерү, искитәрү, таңга (хәйран) калдыру; нык тәэсир итү.

**РАЗИ'ТЬ** II *несов. простореч.*— аңку, аңкып тору; начар ис чыгару, начар ис килү, ис килеп (таралып) тору, ис бәреп тору; *от него разило чесноком* — аңардан сарымсак исе аңкып тора иде.

**РАЗЛАГА'ТЬ** *несов.*— к. разложить II.

**РАЗЛАГА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. разложиться II; 2. бетүгә йөз тоту, черен таркала бару, бозыла бару (әхлак ягыннан); 3. *страд.* аерып алыну, таркатылу.

**РАЗЛАГА'ЮЩИЙ** *книж.*— бозучы, таркатучы, юлдан яздыручы, аздыручы; начар, яман, зарарлы; *разлагающее влияние* — зарарлы тәэсир.

**РАЗЛА'Д** *м. мн.* нет — 1. тәртипсезлек, таркаулык, көйсезлек; бердәмлек булмау; *дело пошло на разлад* — эш көйсезләнеп китте; 2. татусызлык, татулык булмау; дау, низаг, ызгыш, гауга; *семейный разлад* — семьяда татулык булмау.

**РАЗЛА'ДИТЬ** *сов.*— 1. *спец.* бозу, вату; көйсезләндерү; эштән чыгару, төзексезләндерү; *разладить часы* — сәгатьне бозу; *разладить скрипку* — скрипканы көйсезләү; 2. *разг.* (эшне) бозу, бозып кую, рәтен җибәрү, таркату.

**РАЗЛА'ДИТЬСЯ** *сов.*— 1. *спец.* бозылу, ватылу; көйсезләнү, тәзексезләнү, эштән чыгу; *станок разладился* — станок бозылды; 2. *разг.* эш бозылу, сүтелү, тар (к)алу; рәте (жае) китү; *дело разладилось* — эшнең рәте китте; 3. *разг.* көйсезләнү, көе китү, көе бозылу, аһәңе (тавышы) бозылу; *балалайка разладилась* — балалайка көйсезләнгән.

**РАЗЛА'ДИЦА** *ж. просторечь.*— к. разлад.

**РАЗЛА'ЖЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *спец.*— бозылганлык, ватылганлык, тәзексезлек; көйсезлек, көйсезләнгәнлек.

**РАЗЛА'ЖЕННЫЙ** — бозык, бозылган көйсез, көе киткән, рәте киткән, тәзек булмаган; эштән чыккан, ватык, ватылган; *разлаженная машина* — ватык машина.

**РАЗЛА'ЖИВАТЬ** *несов.*— к. разладить.

**РАЗЛА'ЖИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. разладиться; 2. *страд. разг.* таркатылу, рәте җибәрелү.

**РАЗЛА'КОМИТЬ** *сов. разг.*— 1. тәмле ашыйсыны китерү, сыйланасыны китерү; 2. тәмлегә өйрәтү, тәмле тамакландырып җибәрү, тәмлегә өйрәтеп җибәрү; *волжская рыба разлакомила его* — Идел балыгы аның авызын тәмлегә өйрәтте; 3. *перен. фам.* нәфесен уяту; бик ошау, бик ошап китү; *выигрыш разлакомил его* — отыш аңа бик ошап китте.

**РАЗЛА'КОМИТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. тәмле тамакланып китү, тәмлегә өйрәнеп китү, сыйланырга ярата башлау; авызы тәмлегә өйрәнү; 2. *перен. фам.* бик ошап китү, кызыгып китү, нәфесенә бирелү.

**РАЗЛА'МЫВАТЬ** *несов.*— к. разломать.

**РАЗЛА'МЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. разломаться; 2. *страд.* сындырып (ватып) бетерелү.

**РАЗЛА'ПУШКА** *ж. разг. фам.* и *обл.*— җанкаем, җаным.

**РАЗЛА'ПЫЙ** *спец.* **разлапый лист** — табан яфрак; **разлапый корень** — тармаклы тамыр (аерылган бармаклар кебек).

**РАЗЛА'ЯТЬСЯ** *сов. просторечь.* — 1. бик каты өрә башлау, һау-һаулап өрергә ябышу; *за околицей собаки разлаялись* — авыл читендә этләр бик каты өрә башлады; 2. *перен.* әрләшә башлау, эт кебек өрә башлау, кычкырышырга (орыш ышырга) тотыну, чиктән тыш сүгенү; *ну, что ты разлаялся?* — я, син нигә эт кебек өрә башладың? 3. ачуланышу, бозылышу.

**РАЗЛЕЖА'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.*— озак аунап яту, (озак ятып) урыныннан торасы килмәү, иренеп яту, ялкауланып яту.

**РАЗЛЁЖИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— к. разлежаться.

**РАЗЛЕЗА'ТЬСЯ** *несов. просторечь.*— к. разлезться.

**РАЗЛЕ'ЗТЬСЯ** *сов. просторечь.*— 1. күзе китү, җебе китү (мәсәлән, оекның); 2. сыпылу, сыпылып чыгу, сизерәп бетү, ертылып (тетелеп, сәләмәләнеп) бетү; *платье разлезлось* — күлмәк сизерәп беткән; 3. ишелү, ишелеп төшү, җимерелеп төшү; *кирпичная кладка разлезлась* — кирпеч стена ишелеп төшкән.

**РАЗЛЕ'НИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— ялкаулану, ялкауланып яту, нәкәсләнеп (эшсез) яту, ялкаулыкка сабышу.

**РАЗЛЕНИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— ялкауланып китү, ялкауланып бетү, нәкәсләнү; эшсезлеккә бирелү, ялкаулык басу.

**РАЗЛЕПИ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. кубару, куптару; куптарып алу, аерып алу; *разлепить склеившиеся страницы в книге* — китаптагы ябышкан битләрне куптару; 2. ябыштырып чыгу, ябыштырып бетерү; *разлепить повсюду объявления* — бөтен җиргә белдерүләр ябыштырып чыгу.

**РАЗЛЕПИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— кубу, аерылу; кубып чыгу, кубып төшү, кубып бетү.

**РАЗЛЕПЛЯ'ТЬ** *несов. разг.*— к. разлепить.

**РАЗЛЕПЛЯ'ТЬСЯ** *несов. разг.*— 1. к. разлепиться; 2. *страд.* кубарылу, куптарылу, куптарып алыну; 3. *страд.* ябыштырылу ябыштырып чыгылу.

**РАЗЛЁТ** *м. мн.* нет, *разг.*— 1. к. разлететься 1; ◇ **Перескочить с разлёту** — чабып барып (йөгереп килеп) сикереп чыгу.

**РАЗЛЕТА'ЙКА** *ж. разг.*— япанча, җилбәгәй плащ (җилкәгә салып төймәләмичә киелә торган җиңелчә өс киеме).

**РАЗЛЕТА'ТЬСЯ** I *несов.*— 1. к. разлететься; 2. *разг.* ачылып китү, күтәрелеп китү (күлмәк итәге, чабу һ. б. турында).

**РАЗЛЕТА'ТЬСЯ** II *сов. разг.*— бик күп (озак) очу, очып йөрү, очып әйләнү-тулгану.

**РАЗЛЕТЕ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. (очып) таралу, төрле якка очып китү; *птицы разлетелись* — кошлар төрле якка очып киттеләр; 2. *перен.* чәчелү, таралу, туз(ыл)у; чәчелеп (таралып) китү, оча башлау; *страницы рукописи разлетелись по полу* — кулъязма битләре идәнгә чәчелеп китте; 3. *перен. разг. (разбиться на части)* ватылу, ватылып чәчелү, уалу, челпәрәмә килү; 4. *перен. разг. фам.* (һавага) очу, юкка чыгу; *надежды разлетелись* — өметләр (һавага) очты; 5. *просторечь.* уктай атылып керү, йөгереп килеп керү; *он разлетелся прямо в кабинет* — ул туп-туры кабинетка уктай атылып керде. ◇ **Разлететься в пух и прах** — пыран-заран килү. **Разлетевшись, ударился о столб** — кызу очып (чабып) килеп баганага бәрелде.

**РАЗЛЕ'ЧЬСЯ** *сов.*— сузылып (җәелеп, таралып) яту; иркенләп (аунап, рәхәтләнеп) яту; *разлечься на диване* — диванга сузылып яту.

**РАЗЛИ'В** — 1. ташу, ташкын; су җәелү; *разлив реки* — елганың ташуы; 2. *спец.* (төрле савытларга) бүлеп тутыру, тутырып (салып, агызып) чыгу; *разлив вина по бутылкам* — кызыл аракыны шешәләргә тутырып чыгу; 3. *обл.* су баскан тугай, су җәелгән урын.

**РАЗЛИВА'ННЫЙ**: **разливанное море** *разг. шутл.*— 1. эчү мәҗлесе, кәеф-сафа

мәҗлесе; 2. күплек, муллык, дәрья (эчемлек турында).

**РАЗЛИВА'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. соса торган; *разливательная ложка* — аш соса торган кашык (аш чүмече); 2. бүлеп тутыра торган.

**РАЗЛИВА'ТЬ** *несов.* — к. разлить.

**РАЗЛИВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. разлиться; 2. *перен.* чут-чут итеп сайрау; *соловей разливается* — сандугач чут-чут итеп сайрый; 3. *перен. разг. фам. ирон.* сайрау, ялагайланып сөйләү, тәмле теллеләнү; *как он разливается!* — кара син аны, ничек сайраган була! 4. *страд.* (савытларга бүлеп) тутырылу, салыну, бушатылу, аударылу, агызылу (мәсәлән, сөт); 5. коелу (мәсәлән, сыек металл).

**РАЗЛИ'ВКА** *ж. мн.* нет, *спец.* — к. разлить 1; *разливка вина* — (савытларга) аракы агызып тутыру; *разливка металла в изложницы* — эрегән металлны калыпларга агызу, коюю.

**РАЗЛИВНО'Й** — 1. к. разливательный; 2. бүлеп сатыла (тутырыла) торган; агызып тутырылмалы; *разливное вино* — бүлеп сатыла торган кызыл аракы.

**РАЗЛИ'ВОЧНЫЙ** *спец.* — к. разливательный.

**РАЗЛИ'ВЩИК** *м. спец.* — 1. (агызып) тутыручы, тутырып торучы (мәсәлән, аракыны шешәләргә тутыручы); 2. коючы (эретелгән металлны калыпларга агызып коючы).

**РАЗЛИЗА'ТЬ** *сов. просторeч.* — ялап буяп бетерү, ялап пычратып бетерү.

**РАЗЛИ'ЗЫВАТЬ** *несов. просторeч.* — к. разлизать.

**РАЗЛИМО'НИТЬ** *сов. просторeч. фам.* — исертү (аракы белән), сәрхуш итү.

**РАЗЛИМО'НИТЬСЯ** *сов. просторeч. фам.* — исерү, сәрхуш булу; изрәп төшү.

**РАЗЛИ'Н** *м. просторeч.* — ябага коюю, кабык салу, төс алмаштыру вакыты (хайваннарда һәм кошларда).

**РАЗЛИНЕВА'ТЬ** *сов.* — к. разлиновать.

**РАЗЛИНЁВКА** *ж. спец.* — к. разлиновка.

**РАЗЛИНЁВЫВАТЬ** *несов.* — к. разлиновать.

**РАЗЛИНЁВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — к. разлиновываться.

**РАЗЛИНОВА'ТЬ** *сов.* — (сызыклар) сызып чыгу, сызыклап чыгу; *разлиновать тетрадь* — дәфтәргә сызыклар сызып чыгу.

**РАЗЛИНО'ВКА** *ж. спец.* — 1. *только ед.* к. разлиновать; 2. *(совокупность линий)* сызыклар; 3. *(способ разлиновки)* сызылыш, сызу рәвеше.

**РАЗЛИНО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. разлиновать.

**РАЗЛИНО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — сызылу, сызыклар сызылу, сызып чыгылу.

**РАЗЛИПА'ТЬСЯ** *несов. разг.* — к. разлипнуться.

**РАЗЛИ'ПНУТЬСЯ** *сов. разг.* — кубу; кубып чыгу, кубып төшү.

**РАЗЛИ'ТИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — 1. к. разлить 1, 2; 2. к. разлиться 1, 2, 3, 4; *разлитие реки* — елганың ташуы, ярдан чыгуы. ◇ **Разлитие желчи** *(мед.)* — үтнең тәнгә таралуы (мәсәлән, үт куыгы сытылып).

**РАЗЛИ'ТЬ** *сов.* — 1. (зур савыттан кечкенәгә) бүлеп тутыру, салу, агызу, бушату; (агызып) салып чыгу, тутырып чыгу; *разлить вино по бутылкам* — кызыл аракыны шешәләргә тутыру (мәс., мичкәдән); 2. (чайкалдырып) түгү, түгеп җибәрү, түгеп бетерү; *разлить вино на скатерть* — эскәтергә аракы түгү; 3. *книж.* ярларыннан чыгып җәелү, ташып чыгу; су басу; *река разлила свои воды* — елга суы ярларыннан чыгып җәелде; 4. *книж.* тарату; *цветы разлили благоухание* — чәчәкләр хуш ис тараткан; 5. *книж.* (нур) чәчү, сибү, кою; *солнце разлило свои лучи* — кояш үзенең нурларын сипте. ◇ **Разлить щедроты** — юмартлыклар яудыру. **Разлить милости** — шәфкать күрсәтү, мәрхәмәт күрсәтү. **Разлить чай** — чәй ясау. **По лицу его разлита нежности** (Чехов) — аның йөзендә мөлаемлык балкый. **Водой не разольёшь** — к. вода.

**РАЗЛИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. түгелү, түгелеп китү, чайкалып түгелү; *вино разлилось по скатерти* — эскәтергә кызыл аракы түгелде; 2. *разг.* бүле(не)п салыну, тутырылу (мәсәлән, сыеклык); *вся масса разлилась по бутылкам* — бөтен сыеклык шешәләргә тутырылып бетте; 3. ташу, ярдан чыгу; су җәелү, су басу; *река разлилась* — елга ярларыннан чыкты; 4. *перен.* таралу, җәелү; чәчелү, сибелү; *разлились потоки света* — яктылык нурлары сибелде; 5. *разг.* к. разливаться 2, 3.

**РАЗЛИХО'Й** *разг.* — бик чая, бик кыю, бик житез.

**РАЗЛИЧА'ТЬ** *несов.* — к. различить.

**РАЗЛИЧА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. аерылу, аерылып тору; *различаться по возрасту* — яшь ягыннан аерылу (яшь аермасы); *различаться по объёму* — күләм ягыннан аерылу; 2. *страд.* танылу.

**РАЗЛИ'ЧЕСТВОВАТЬ** *несов. книж. устар.* — к. различаться 1.

**РАЗЛИ'ЧИЕ** *ср.* — аерма, аерымлык, аермалык; башкалык, үзгәлек; төрлелек; *различия во взглядах* — караштагы аермалыклар. ◇ **Знаки различия** *офиц.* — аеру билгеләре (мәсәлән, хәрби дәрәҗәне күрсәтә торган билгеләр).

**РАЗЛИЧИ'ТЕЛЬНЫЙ** — аеру...-ы; аерымлык...-ы; аера торган, аеручы, аермасын күрсәтә (билгели) торган; аерып тора торган; *различительный признак* — аерымлык билгесе, аера торган билге.

**РАЗЛИЧИ'ТЬ** *сов.* — 1. аерып булу, аерып белү, аера алу; тану, танып алу; таный алу, танып булу; *в темноте трудно различить* — караңгыда тануы авыр, танып булмый; *их не различишь* — аларны аера алмыйсың (бик охшаганнар); *ночью не различишь зелёного от голубого* — төнлә зәңгәр белән яшелне аерып булмый; 2. аеру, билгеләү, билгеләп кую; *различить сорта товара* — товарларның сортын аера алу.

**РАЗЛИ'ЧНО** *нареч.* — төрлечә, икенче төрле итеп, башкача, үзгәчә; *различно пов-*

*торять одно и то же* — бер үк нәрсәне төрлечә кабатлау.

**РАЗЛИ'ЧНЫЙ** — 1. *(неодинаковый, разный)* төрле, үзенә башка, үзенә бер төрле, (бер-берсеннән) аерыла торган; 2. *(разнообразный)* һәртөрле, төрле-төрле; күп төрле.

**РАЗЛО'ГИЙ** *обл.* — сөзәк, сөзәк ярлы, сөзәкләнеп килгән, текә түгел; *разлогий овраг* — сөзәк ярлы ерым.

**РАЗЛО'ГОСТЬ** *ж. мн.* нет, *обл.* — сөзәклек, сөзәк ярлы булу.

**РАЗЛОЖЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — 1. таркату, таркалу, бүлү, бүленү; аеру, аерылу; *разложение воды на составные части* — суны состав өлешләренә таркату (химик юл белән); *разложение на множители* — тапкырлашучыларга таркату; 2. черү, череп таркалу, бозылу; *разложение трупа* — мәетнең черүе (бозылуы); 3. *перен.* таркалу, череп таркалу, бетүгә йөз тоту; *моральное разложение* — мораль яктан череп таркалу; 4. таркалыш; *внести разложение* — таркалыш кертү.

**РАЗЛОЖИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет — таркалучанлык (состав өлешләргә таркалу сәләте).

**РАЗЛОЖИ'МЫЙ** — 1. *мат.* таркатыла торган; *разложимое число* — тапкырлашучыларга таркатыла торган сан; 2. *хим.* таркалучан, таркала торган; *разложимое вещество* — (состав өлешләренә) таркала торган матдә.

**РАЗЛОЖИ'ТЬ** I *сов.* — 1. таратып урнаштыру, таратып ташлау, таратып (урнаштырып) чыгу, таратып кую; *разложить книги по всему столу* — китапларны бәтен өстәлгә таратып кую; 2. таратып салу; *разложить карты* — карталарны таратып салу; карта салу (пасьянс уенында); 3. җәю, җәеп кую, җәеп салу; *разложить скатерть* — эскәтер җәю; 4. бүлү, бүлеп салу; *разложить налог* — налог бүлеп салу; 5. *перен. книж.* (үзара) тигез бүлешү, тигезләп бүлү; *разложить убыток* — күрелгән зарарны бүлешү (тигез күтәрү). ◇ **Разложить костёр (огонь)** — учак яндырып җибәрү, ут ягу.

**РАЗЛОЖИ'ТЬ** II *сов.* — 1. *науч.* (состав өлешләргә) таркату, аеру, бүлү; *разложить воду на кислород и водород* — суны кислород һәм водородка таркату; *разложить слово* — сүзне мәгънәле кисәкләргә аеру; 3. *перен.* таркату, таркалыш кертү; аздыру, бозу (мораль яктан); *разложить армию противника* — дошман армиясен таркату.

**РАЗЛОЖИ'ТЬСЯ** I *сов. разг.* — 1. урнашу, урнашып бетү, сыеп бетү; *все книги разложились в шкафу* — барлык китаплар шкафка урнашып (сыеп) беттеләр; 2. таратып салу, җәеп салу, урнаштырып бетерү; *разложился и начал заниматься* — әйберләрен таратып салды да эшкә тотынды; 3. ачылу, җәелү; *новая складная кровать с трудом разложилась* — яңа җыелма кровать көчкә җәелде; 4. бүленү, салыну, бүлеп салыну (мәсәлән, салым).

**РАЗЛОЖИ'ТЬСЯ** II *сов.* — 1. *науч.* таркалу, аерылу, бүленү; *вода разложилась на кислород и водород* — су кислород һәм водородка таркалды (аерылды); *число разложилось на множители* — сан тапкырлашучыларына таркалды; 2. черү, таркалу, череп таркалу, бозылу; *труп разложился* — мәет черегән; 3. *перен.* таркалу, череп таркалу; бозылу, бозыклыкка бирелү; *армия врага разложилась* — дошман армиясе таркалды (мораль яктан).

**РАЗЛО'М** *м.* — 1. *только ед.* к. разломать; 2. *спец.* к. разломиться, разламываться; 3. ватылган урын, сынган җир; *по линии разлома* — сынган сызыгы буенча; 4. *тех.* сынган урынның, сыну кисеменең төзелеше; *мелкозернистый разлом стали* — сынган корыч кисеменең вак бөртекле төзелеше.

**РАЗЛОМА'ТЬ** *сов.* — 1. вату, сындыру; ваткалап бетерү, сындыр(гала)п ташлау; *разломать палку* — таякны сындырып ташлау; 2. җимерү, җимереп ташлау, ишеп төшерү; *разломать забор* — койманы җимерү.

**РАЗЛОМА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. ватылу, сыну; ватылып чыгу, ватылып бетү; җимерелеп бетү; *стул разломался* — урындык ватылган; 2. *простореч.* боргалана-сыргалана башлау; артык кылану, кыланчыклanып китү.

**РАЗЛОМИ'ТЬ** *сов.* — 1. сындыру, сындырып чыгару, урталай сындыру; *разломить хлеб* — икмәкне урталай сындыру; 2. *простореч. безл.* сызлап җәфалап бетерү, сызлап тенкәгә тию.

**РАЗЛОМИ'ТЬСЯ** *сов.* — сыну, урталай сыну, сынып чыгу; ватылып чыгу.

**РАЗЛО'МКА** *ж. мн.* нет, *спец.* — к. разлом 1, 2.

**РАЗЛО'МЩИК** *м. спец.* — ватучы; ваклаучы; *разломщик камня* — таш ватучы.

**РАЗЛУ'КА** *ж. мн.* нет — 1. читтә яшәү; *жить в разлуке с родными* — туганнардан читтә яшәү; 2. аерылу, аерылышу; *настал час разлуки* — аерылышу сәгате сукты (вакыты җитте).

**РАЗЛУЧА'ТЬ** *несов.* — к. разлучить.

**РАЗЛУЧА'ТЬСЯ** *несов.* — к. разлучиться.

**РАЗЛУЧЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — 1. к. разлучить; 2. *устар.* к. разлука.

**РАЗЛУЧИ'ТЬ** *сов.* — аеру, ераклаштыру.

**РАЗЛУЧИ'ТЬСЯ** *сов.* — аерылу, аерылышу, ераклашу; ташлашу.

**РАЗЛУ'ЧНИК** *м.*, **РАЗЛУ'ЧНИЦА** *ж. простореч. нар.-поэт.* — аеручы, ташлаштыручы, араны бозучы, аерылышуга сәбәп булган кеше.

**РАЗЛЮБИ'ТЬ** *сов.* — яратмый башлау, сөюдән туктау, мәхәббәт суыну, күңел кайту, күңел бизү, бозу.

**РАЗЛЮБЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. разлюбить.

**РАЗЛЮЛИ'**: **разлюли малина** *простореч. фам.* — җиңел (рәхәт, кәефле, иркен) яшәү.

**РАЗМАГНИ'ТИТЬ** *сов.* — 1. *спец.* (металлны) магнитсызлау, магнитсызландыру, магнитын бетерү (тимер-корыч әйберләрнең үзенә тарту үзлеген бетерү); 2. *перен. разг.* тәртипсезләндерү, йөгәнсезләндерү; тыйнаксызландыру, бозу.

**РАЗМАГНИ'ТИТЬСЯ** *сов.* — 1. *спец.* маг-

нитсызлану, магниты бетү; 2. *перен. разг. неодобр.* тәртипсезләнү, бозылу, йөгәнсезләнү; тыйнаксызлану.

**РАЗМАГНИ'ЧЕННЫЙ** — 1. магнитсызлан(дырыл)ган; магнитлык сыйфатларын (үзлекләрен) җуйган; *размагниченная стрелка компаса* — компасның магнитсызланган угы; 2. *перен. разг.* тәртипсез, тыйнаксыз, бозык; сабырсыз, үзен тота алмый торган.

**РАЗМАГНИ'ЧИВАТЬ** *несов.*— к. размагнитить.

**РАЗМАГНИ'ЧИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. размагнититься; 2. *страд.* магнитсызландырылу, магнит үзлеге бетерелү.

**РАЗМА'ЗАТЬ** *сов.*— 1. буяу, ягу; буяп бетерү, сөртеп (сылап) чыгу; буяп (сылап) пычрату; *размазал грязь по лицу* — бөтен битенә пычрак буяган; 2. *разг. пренебр.* ала-кола буяп ташлау, аннан-моннан гына буяштыргалап чыгу, пычрак (шапшак) итеп буяу; 3. *перен. разг. фам. пренебр.* арттырып сөйләү, буташтырып сөйләү.

**РАЗМА'ЗАТЬСЯ** *сов.*— буялу, буялып бетү, пычранып бетү; буялып калу (тап, пычрак).

**РАЗМА'ЗКА** *ж. мн.* нет, *простореч.*— к. размазать 1, 2.

**РАЗМАЗНЯ'** *разг.*— 1. *ж.* сыек ботка; 2. *ж. перен.* пычрак, сыек баткак; 3. *м.* и *ж. перен. разг. пренебр.* булдыксыз, йомшак, җебегән, булмаган кеше, арыш боламыгы; 4. *перен.* болама, буталчыклык, анык-сызлык, төгәлсезлек; *размазня чувств* — хисләр боламасы, хисләр буталчыклыгы.

**РАЗМА'ЗЫВАТЬ** *несов.*— к. размазать.

**РАЗМА'ЗЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. размазаться; 2. *страд.* буяп пычратылу, пычратып бетерелү.

**РАЗМА'ИВАТЬ** *несов. разг.*—к. размаять.

**РАЗМА'ИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— 1. к. размаяться; 2. *страд.* юатылу, мавыктырылу, йокысы таратылу.

**РАЗМАЛЕВА'ТЬ** *сов. разг. пренебр.*— ала-кола буяу, буяштыргалап ташлау, аннан-моннан буяп рәсем ясау.

**РАЗМАЛЁВЫВАТЬ** *несов. разг. пренебр.*— к. размалевать.

**РАЗМАЛЁВЫВАТЬСЯ** *несов. страд. разг. пренебр.*— тупас итеп буялу, аннан-моннан гына буялу.

**РАЗМА'ЛЫВАТЬ** *несов.*— размолоть.

**РАЗМА'ЛЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. размолоться; 2. *страд.* (ашлык) тарттырылу; онга (порошокка) әйләндерелү.

**РАЗМА'НИВАТЬ** *несов. простореч.*— к. разманить.

**РАЗМА'НИВАТЬСЯ** *несов. простореч. страд.*— акрынлап кызыктырылу, бер-бер эшкә котыртылу.

**РАЗМАНИ'ТЬ** *сов. простореч.*— кызыктыру, кызыктырып алдау, акрынлап кызыктыру, теләк уяту, котырту (бер-бер эшкә).

**РАЗМА'РИВАТЬ** *несов. разг.*— к. разморить.

**РАЗМА'РИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— к. размориться.

**РАЗМА'ТЫВАТЬ** *несов.*— к. размотать.

**РАЗМА'ТЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. размотаться 1; 2. *страд.* сүт(әл)еп алыну.

**РАЗМА'Х** *м. мн.* нет — 1. *(действие)* к. размахать, размахивать; размахнуться 1; *размах дубиной* — күсәк белән селтәнү (кизәнү); 2. *(сила взмаха)* кизәнү көче; селтәнеш, кизәнеш; 3. *спец.* (җәелгән) кул арасы, колач; канат очлары арасы; *размах крыльев самолёта* — самолёт канатларының очлары арасы; 4. *тех. (амплитуда)* тирбәлү киңлеге, тибрәнү колачы, чайкалу арасы; 5. *перен.* эшчәнлек киңлеге (күләме, колачы); җәелеш, колач; *соревнование приняло широкий размах* — ярыш киң колач алды; 6. *перен. разг.* иркенлек, муллык, бай-мул тормыш, киң колач белән яшәү. ◇ **Бросить с размаху** — селтәп җибәрү, селтәп ыргыту. **Ударить с размаху** — кизәнеп сугу. **Удариться со всего размаху** — кызу йөгереп килеп бәрелү.

**РАЗМАХА'ТЬ** *сов. простореч.*— 1. к. раскачать; 2. селтәү, болгау.

**РАЗМАХА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— (бертуктаусыз) селтәнү, селтәнә (селти) башлау; *размахаться руками* — куллары белән селтәнә башлау.

**РАЗМА'ХИВАТЬ** *несов.*— (як-якка) селтәү, болгау, кул изәү; селтәп йөрү; *размахивать руками при ходьбе* — йөргәндә кулларын селтәп йөрү.

**РАЗМА'ХИВАТЬСЯ** *несов.*— к. размахнуться.

**РАЗМАХНУ'ТЬ** *сов.*— 1. селтәү, селтәп җибәрү, кизәнү; *размахнуть дубиной* — күсәк белән кизәнү; 2. *простореч. (о качелях)* этеп җибәр. селкетеп җибәрү, атынлырып җибәрү.

**РАЗМАХНУ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. кизәнү, селтәнү; кул күтәрү (сугарга); *размахнуться и ударить* — кизәнеп сугу; 2. *перен. разг.* артык киң җәелү, киң колач алу (тормышта, эштә).

**РАЗМА'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. размочить.

**РАЗМА'ЧИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. размочиться; 2. *страд.* җебетелү, чылатылу; суда җебетеп йомшартылу, бөрттерелү.

**РАЗМАЧТОВА'ТЬ** *сов. мор.*—(корабльнең) мачталарын алу; мачталарны сүтеп алу (алып ташлау).

**РАЗМАЧТО'ВЬВАТЬ** *несов. мор.*— к. размачтовать.

**РАЗМАЧТО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд. мор.*— корабльнең мачтасы (сүтеп) алыну; мачталар сүтеп (алып) ташлану.

**РАЗМА'ШИСТО** *нареч.*— 1. сирәк итеп, ара калдырып, киң алдырып; *размашисто писать* — сирәк итеп язу; 2. киң колачлап, киң алдырып; *размашисто грести* — киң колачлап ишү; 3. *перен.* иркен, бай, мул; үкертеп; *размашисто жить* — иркен тормыш белән яшәү.

**РАЗМА'ШИСТОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.*— киңлек, иркенлек, киң колачлылык.

**РАЗМА'ШИСТЫЙ** *разг.*— 1. киң, киң адымлы, киң колачлы; *размашистый шаг* — киң адымлы йөреш; 2. сирәк, киң, ара калдырылган (язу турында); 3. *перен.* таркау, тәртипсез, чуалчык; *размашистый стиль* — таркау стиль; 4. *перен.* иркен, мул; киң,

берии белән дә чикләнмәгән; *размашистое гостеприимство* — киң кунакчыллык.

**РАЗМА'ЯТЬ** *сов. разг.* — йокысын ачу, эч пошуны бетерү, күңелне ачу, күңелне күтәреп җибәрү.

**РАЗМА'ЯТЬСЯ** *сов. разг.* — йокы ачылу, йокы таралу; күңел ачылу, күңел күтәрелү.

**РАЗМЕЖЕВА'НИЕ** *ср. мн.* нет — к. размежевать, размежеваться. ◇ **Идейное размежевание** — идея ягыннан аерылу, фикри аерылышу.

**РАЗМЕЖЕВА'ТЬ** *сов.* — 1. чик үткәрү, чик сызу; межалап (ызанлап) бүлеп чыгу; *размежевать землю* — җирне межалап бүлеп чыгу; 2. *перен. книж.* чикләү, чикләрен билгеләү, чикләп күрсәтеп чыгу, (эш чикләрен) аерып билгеләп кую; *размежевать сферы деятельности* — эшчәнлек даирәсенең чикләрен билгеләү (аерып билгеләп кую).

**РАЗМЕЖЕВА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. чик белән аерылу, чик сызылу; межалап бүленү; 2. *перен. книж. (разграничить предел деятельности)* эш чикләрен билгеләү, эшләрне бүлешү; 3. *книж.* фикердә аерылышу, карашта аерылышу.

**РАЗМЕЖЁ'ВКА** *ж. мн.* нет, *разг.* — к. размежевание.

**РАЗМЕЖЁВЫВАТЬ** *несов.* — к. размежевать.

**РАЗМЕЖЁВЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. размежеваться.

**РАЗМЕЛЬЧА'ТЬ** *несов.* — к. размельчить.

**РАЗМЕЛЬЧА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. размельчиться; 2. *страд.* вакланылу, ваклап бетерелү.

**РАЗМЕЛЬЧИ'ТЬ** *сов.* — ваклау, вагайту, ваклап бетерү; төю; *размельчить пшено* — тары ярмасын төю.

**РАЗМЕЛЬЧИ'ТЬСЯ** *сов.* — вaклану, вагаю; вакланып, вагаеп бетү; төелү.

**РАЗМЕ'Н** *м. мн.* нет — 1. ваклау, вату; *размен денег* — акча ваклау; 2. алмашу; алыштыру, алмаштыру; *размен пленных* — әсирләрне алмашу; 3. (фигураларны) алышу, сугып алышу (мәсәлән, шахматта).

**РАЗМЕ'НИВАТЬ** *несов.* — к. разменять.

**РАЗМЕ'НИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. разменяться; 2. *страд.* вaклану, вәкка алмаштырылу (акча); 3. *страд.* алыштырылу, алмаштырылу (шахмат уенында).

**РАЗМЕ'ННЫЙ: разменные деньги, разменная монета** — вак акча (көмеш яки бакыр акча).

**РАЗМЕНЯ'ТЬ** *сов.* — ваклау, вату; ватып (ваклап) бирү; вакка алмаштыру; *разменять деньги* — акча ваклау.

**РАЗМЕНЯ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. *разг. спец.* алышу, алмашу; *разменяться концами* — очларын алмашып тоту; *разменяться пешками* — пешкаларны алышу (ашашу); 2. *простореч.* вaклану, алмаштырылу (акча турында). ◇ **Разменяться на мелочи** *перен. неодобр.* (көч, сәләтне) вак-төяккә әрәм итү, юк-барга сарыф итү.

**РАЗМЕ'Р** *м.* — 1. зурлык (озынлык, киңлек яки биеклек); *комната средних размеров* — уртача зурлыктагы бүлмә; *размер палки — полметра* — таякның озынлыгы ярты метр; 2. микъдар; күләм; *размер зарплаты* — эш хакының күләме; 3. *(мерка, номер вещи)* үлчәм, үлчәү, размер, номер; *размер галош* — галошның үлчәве (номеры); 4. *лит. муз.* үлчәү, вәзен; *размер стиха* — шигырь үлчәве; 5. *перен. мн. (степень охвата, развития)* күләм, колач, дәрәҗә. ◇ **Какой размер ботинок носишь?** — син ничәнче ботинка киясең? **Я ношу сорок первый размер** — мин кырык берле ботинка киям. **В размере** — 1. исәбеннән (чыгып) *взимать пеню в размере 0,01% в день* — көненә 0,01% исәбеннән пеня алу; 2. масштабында, нисбәтендә; *план снят в размере ста метров в сантиметре* — план бер сантиметрда йөз метр масштабында төзелде. **Удержать в полном размере** — тулысынча (тулы бәясен) тотып калу. **В трехкратном размере** — өч тапкыр артыграк (тоту, түләтү).

**РАЗМЕ'РЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — салмаклык, тигезлек, ритмлылык, бер үлчәүгә буйсынганлык.

**РАЗМЕ'РЕННО** *нареч.* — салмак кына, тигез генә, бертигез, ритм белән; *размеренно звучать* — салмак кына ишетелү.

**РАЗМЕ'РЕННЫЙ** *книж.* — салмак, бер үлчәүле; ритмлы; *размеренная походка* — салмак адым белән йөрү; *размеренные движения* — ритмлы хәрәкәтләр.

**РАЗМЕ'РИТЬ** *сов.* — 1. *спец.* (әйберләрнең зурлыгын) үлчәп чыгу, үлчәп билгеләп кую; *размерить место для постройки* — каралты өчен кирәкле урынны үлчәп билгеләп кую; 2. *перен.* билгеләү, чамалап карау, сынап карау; *размерить свои силы* — үз көчеңне сынап карау; 3. *обл.* үлчәп бүлү, бүлеп чыгу; *размерить поле на гектары* — кырны гектарларга бүлеп чыгу.

**РАЗМЕ'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *физ.* — үлчәнеш; *размерность скорости* — тизлек үлчәнеше.

**РАЗМЕ'РНЫЙ** *книж.* — тигез үлчәүле, ритмлы, салмак.

**РАЗМЕРЯ'ТЬ** *несов.* — к. размерить.

**РАЗМЕРЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — үлчәп бүленү, үлчәп чыгылу, үлчәп куелу; үлчәп зурлыгы билгеләнү.

**РАЗМЕСИ'ТЬ** *сов.* — 1. (яхшылап) басу, изү; *размесить глину* — балчык изү; 2. (су кушып) болгату; изү, тугылау; *размесить известь* — известьне суда изү.

**РАЗМЕСИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — яхшылап басылу, изелү; тугылану.

**РАЗМЕСТИ'** *сов.* — 1. себерү, себереп чыгу; *размести дорожку* — сукмакны себереп чыгу; 2. (төрле якка) себереп юл ачу; себереп ташлау, көрәп ташлау; *размести снег* — карны себереп юл ачу.

**РАЗМЕСТИ'ТЬ** *сов.* — 1. урнаштырып кую, урнаштырып чыгу; куеп чыгу, таратып кую; *разместить товары по полкам* — товарларны киштәләргә урнаштырып кую; 2. *(найти каждому место)* урнаштырып бетерү, сыйдырып бетерү; урын табу

(барысына да); 3. *перен.* тарату, урнаштыру; *разместать заём* — заём тарату.

**РАЗМЕСТИ'ТЬСЯ** *сов.* — урнашу, урнашып бетү, сыеп бетү; (урыннарына) утыр(ыш)у, урын алу; *все гости разместились за столом* — кунаклар барысы да өстәл янына утырыштылар.

**РАЗМЁТ** *м. спец.* — 1. аяк басыш киңлеге (этләргә карата); 2. *обл.* таратып җәю (печәнне)

**РАЗМЕТА'ТЬ** I *несов.* — к. размести.

**РАЗМЕТА'ТЬ** II *сов.* — 1. туздыру, тарату, тузгыту; төрле якка ыргыту; туздырып бетерү, таратып (чәчеп) ташлау; *буря разметала солому* — давыл саламны туздырып ташлады; 2. *обл.* таратып җәю; *разметать сено для просушки* — киптерү өчен печәнне таратып җәю; 3. *устар.* туздыру, тар-мар итү, пыран-заран китерү; *разметать врагов* — дошманнарны тар-мар итү; 4. *разг.* таралып яту, җәелеп утыру (килешсез рәвештә).

**РАЗМЕТА'ТЬСЯ** I *несов. страд.* — себерелү, себереп чыгарылу, себереп куелу; себереп (көрәп) ташлану.

**РАЗМЕТА'ТЬСЯ** II *сов.* — 1. *разг.* тынычсызлана башлау, як-якка әйләнгәли башлау; борсалану (тынычсыз йоклаганда саташканда); *больной разметался в бреду* — авыру саташып як-якка әйләнгәли башлады; 2. таралып (сузылып, җәелеп, иркенләп) яту, аяк-кулларын җәеп яту; *ребёнок разметелся на постели* — бала аяк-кулларын җәеп ятган.

**РАЗМЕ'ТИТЬ** *сов.* — тамга салып (билге куеп) чыгу; билгеләү, тамгалау; *разметить шрифты в рукописи для набора* — кулъязманы наборга бирү өчен шрифтларын билгеләп чыгу (нинди хәрефләр белән җыюны күрсәтү өчен).

**РАЗМЕ'ТКА** *ж* — 1. *только ед.* к. разметить; 2. *(знак, метка)* билге, тамга; 3. *только ед. тех.* разметка ясау, тамгалау (сызым буенча эшләгәндә, аның сызыкларын һәм нокталарын эшкәртелә торган материалга күчерү); 4. *тип.* разметка, разметка кәгазе (наборның ничек битләргә салынырга тиешлеге күрсәтелгән кәгазь); 5. *спец.* разметка нөсхәсе (мәкаләләре басылган авторларның гонорар күләме билгеләнгән газета-журнал нөсхәсе).

**РАЗМЁТКА** *ж. мн.* нет, *спец.* — к. размёт 2.

**РАЗМЕ'ТЧИК** *м.*, **РАЗМЕ'ТЧИЦА** *ж.* — билге (разметка) ясаучы, билгеләүче, тамгалаучы; *разметчик вагонов* — вагоннарны тамгалаучы.

**РАЗМЁТЫВАТЬ** *несов.* — к. разметать II.

**РАЗМЁТЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. разметаться II; 2. *страд.* таратылу, туздырылу, таратып ташлану, туздырып ташлану; тар-мар ителү (дошман явы); таратып җәелү, таратып куелу (мәсәлән, печән).

**РАЗМЕЧА'ТЬ** *несов.* — к. разметить.

**РАЗМЕЧА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — билгеләр куелу, тамгалар куеп чыгылу; разметка ясалу.

**РАЗМЕ'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. разметить.

**РАЗМЕ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — к. размечаться.

**РАЗМЕЧТА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — уйга бирелеп китү, хыялга бату, хыялга чуму.

**РАЗМЕША'ТЬ** *сов.* — болгату, бутау; тугылау, болгатып эретү, изү, аралаштыру, катыштыру.

**РАЗМЕША'ТЬСЯ** *сов. разг.* — кушылу, аралашу; буталу, тугылану, (болганып) эреп бетү.

**РАЗМЕ'ШИВАТЬ** I *несов.* — к. размесить.

**РАЗМЕ'ШИВАТЬ** II *несов.* — к. размешать.

**РАЗМЕ'ШИВАТЬСЯ** I *несов.* — 1. *разг.* к. размеситься; 2. *страд.* яхшылап басылу, яхшылап изелү.

**РАЗМЕ'ШИВАТЬСЯ** II *несов.* — 1. *разг.* к. размешаться; 2. *страд.* болгатылу, аралаштырылу; тугылап катыштырылу, болгатып изелү, эретелү.

**РАЗМЕЩА'ТЬ** *несов.* — к. разместить.

**РАЗМЕЩА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. разместиться; 2. *страд.* урнаштырылу, урнаштырып куелу; таратылу, таратып урнаштырылу.

**РАЗМЕЩЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед.* к. разместить; 2. *только ед.* урнаштырылыш, урнаштыру (урнашу тәртибе); *размещение производительных сил в СССР* — СССРда җитештерүче көчләрнең урнаштырылышы; 3. *только мн. мат.* урынлаштырмалар; *размещения с повторениями* — кабатлы урынлаштырмалар.

**РАЗМИНА'ТЬ** *несов.* — к. размять.

**РАЗМИНА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. размяться; 2. *страд.* угалап йомшартылу (мәсәлән, тире); изелү, үзләндерелү (мәсәлән, балчык); язылу (аяк-кул).

**РАЗМИНИ'РОВАНИЕ** *ср. мн.* нет — к. разминировать.

**РАЗМИНИ'РОВАТЬ** *сов. воен.* — минасызландыру, миналардан чистарту (арындыру).

**РАЗМИНУ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — 1. аймылышу, аймыл(ыш) булу; очраша алмау, очрашмыйча (күрмичә) үтеп китү; *мы с ним разминулись* — без аның белән аймылыштык (очраша алмадык); 2. юл бирешү, юл сабу (очрашканда юл биреп үтеп китү); *дорожка узенькая, разминуться нельзя* — юл тар, юл бирешеп үтеп китәрлек түгел.

**РАЗМНОЖА'ТЬ** *несов.* — к. размножить.

**РАЗМНОЖА'ТЬСЯ** *несов.* — к. размножиться; 2. *страд.* үрчетелү; саны арттырылу, күбәйтелү, ишәйтелү.

**РАЗМНОЖЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — к. размножить, размножиться; *половое размножение* — җенесле үрчү; *бесполое размножение* — җенессез үрчү; *размножение почкованием* — бөреләнеп үрчү; *размножение делением* — бүленү юлы белән үрчү.

**РАЗМНО'ЖИТЬ** *сов.* — 1. арттыру, күбәйтү; *размножить рукопись* — кулъязманың санын күбәйтү; 2. үрчетү, үстерү; ишәйтү; *размножить кроликов* — йорт куяннары үрчетү; *размножить растения* — үсемлекләр үстерү.

**РАЗМНО'ЖИТЬСЯ** *сов.* — 1. арту, күбәю; 2. үрчү, үрчеп китү, ишәеп (күбәеп) китү;

*мухи размножились* — чебеннәр үрчеп киткән.

**РАЗМОЗЖА'ТЬ** *несов.* — к. размозжить.

**РАЗМОЗЖА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — к. размозжиться.

**РАЗМОЗЖИ'ТЬ** *сов.* — **1.** сугып яру, сугып изү; *размозжить голову* — сугып башын яру; **2.** *безл.* чәрдәкләнү, чарпаланып бетү; *ему размозжило ногу* — аның аяк сөякләре чәрдәкләнеп (чарпаланып) беткән.

**РАЗМОЗЖИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — сугып ярылу, изелеп бетү; (сугудан сөяк) чарпалану, чәрдәкләнеп бетү.

**РАЗМО'ИНА** *ж.* — ерганак, чокыр (су белән ашалган урын).

**РАЗМОКА'ТЬ** *несов.* — к. размокнуть.

**РАЗМО'КЛЫЙ** *простореч.* — бүрткән, күпкән, җебегән, чыланган.

**РАЗМО'КНУТЬ** *сов.* — суда йомша(р)у, бүртү, күбү, җебү; юешләнү, чылану.

**РАЗМОКРОПОГО'ДИТЬ** *безл. сов. разг.* — к. размокропогодиться.

**РАЗМОКРОПОГО'ДИТЬСЯ** *безл. сов. разг.* — явымнар (яңгырлы көннәр) башлану.

**РАЗМО'Л** *м. мн.* нет — **1.** к. размолоть; **2.** *с.-х.* (онның) тартылышы, тартылу сыйфаты.

**РАЗМОЛА'ЧИВАТЬ** *несов. спец.* — к. размолотить.

**РАЗМОЛА'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* — к. размолотиться.

**РАЗМО'ЛВКА** *ж.* — бозылышып (ачуланышып) алу, дуслык бетеп тору, сүзгә килешү.

**РАЗМОЛОТИ'ТЬ** *сов. спец.* — (ашлык сукканда) ватып бетерү, яньчеп бетерү (мәсәлән, бөртекне).

**РАЗМОЛОТИ'ТЬСЯ** *сов.* — **1.** *спец.* ашлык сукканда ватылу, ватылып чыгу, яньчелеп бетү; **2.** *простореч.* кызып ашлык сугу, (ашлык сугу белән) мавыгып киту; *молотильщики размолотились* — ашлык сугучылар бик мавыгып киттеләр.

**РАЗМОЛО'ТЬ** *сов.* — **1.** тарттыру (онга әйләндерү); *размолоть пшеницу* — бодай тарттыру; **2.** (*растереть в порошок*) төю, порошокка әйләндерү.

**РАЗМОЛО'ТЬСЯ** *сов.* — **1.** тартылу; онга әйләнү; **2.** төелү, порошокка әйләнү; **3.** *спец.* (ышкылып) тузу, эштән чыгу; *жернова размололись* — тегермән ташлары тузган; **4.** *перен. простореч. неодобр.* юкны чәйни (лыгырдый) башлау, артык күп сөйләнү.

**РАЗМО'ЛЬЩИК** *м. спец.* — тарт(тыр)учы, төюче; *размольщик кофе* — кофе тартучы (төюче).

**РАЗМОРИ'ТЬ** *сов., чаще безл. разг.* — (бөркүдән) әлсерәтү, хәлсезләндерү, изрәтү, хәлдән тайдыру; *от жары меня совсем разморило* — эсселек мине тәмам әлсерәтте.

**РАЗМОРИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — (эсселектән яки арудан) әлсерәү, хәлсезләнү, хәлдән таю, хәл бетү, изрәү; алҗып бетү, изрәп (әлсерәп) төшү.

**РАЗМОТА'ТЬ** *сов.* — (уралган, чорналганны) сүтү, сүтеп алу, чишү; *размотать верёвку* — бауны сүтү; *размотать повязку с раны* — ярадан бәйләвечне сүтеп алу.

**РАЗМОТА'ТЬСЯ** *сов.* — **1.** сүтелү, чишелү, сүтелеп китү; *клубок размотался* — йомгак сүтелде; **2.** *простореч.* урау (чорнау) белән мавыгып китү.

**РАЗМО'ТКА** *ж. мн.* нет, *спец.* — **1.** к. размотать; *размотка пряжи* — чорналган җепне сүтү; **2.** йомгак.

**РАЗМО'ТЧИК** *м.*, **РАЗМО'ТЧИЦА** *ж. спец.* — (чорналган әйберне) сүтүче эшче.

**РАЗМОТЫ'ЖИВАТЬ** *несов. обл.* — к. размотыжить.

**РАЗМОТЫ'ЖИТЬ** *сов. обл.* — китмәнләп чыгу, китмән белән йомшарту.

**РАЗМОЧА'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. размочалить.

**РАЗМОЧА'ЛИВАТЬСЯ** *несов.* — **1.** к. размочалиться; **2.** *страд.* мунчалага әйләндерелү, мунчалаландырылу, тетеп (сүсәртеп) бетерелү; **3.** *страд.* какшатылу, бозылу, (саулык, нерв һ. б. ш. турында).

**РАЗМОЧА'ЛИТЬ** *сов.* — **1.** *спец.* мунчалаландыру, сүсәртү; мунчалаландырып (сүсәртеп) бетерү; **2.** *перен. разг. фам.* какшатып бетерү, бозып бетерү; *размочалить здоровье* — саулыкны какшатып бетерү.

**РАЗМОЧА'ЛИТЬСЯ** *сов.* — **1.** *спец.* мунчалалану, мунчалага әйләнү, мунчалага әйләнеп бетү, сүсәрү; сүсәреп (тетелеп, мунчалаланып) бетү; **2.** *перен. разг. фам.* бозылу, какшау, какшап бетү; *нервы совсем размочалились* — нервлар тәмам какшап бетте.

**РАЗМОЧИ'ТЬ** *сов.* — **1.** (суда) чылату, җебетү; юешләтү, чылатып бүрттерү, йомшарту; *размочить сухари* — сохари җебетү. **2.** (аяк астын) пычрату, изрәтү.

**РАЗМОЧИ'ТЬСЯ** *сов.* — (суда) җебү, юешләнү, йомшару, бүртү; чылану (җир) пычрану, изрәү.

**РАЗМО'ЧКА** *ж. мн.* нет, *спец.* — к. размочить.

**РАЗМУСО'ЛИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. размусолить.

**РАЗМУСО'ЛИВАТЬСЯ** *несов. страд. простореч.* — селәгәйләп пычратылу, катырылу.

**РАЗМУСО'ЛИТЬ** *сов. простореч.* — **1.** селәгәйләп пычрату, катыру, майландырып бетерү; **2.** *перен. фам. презрит.* артык озайтып сөйләү, болгатып сөйләү.

**РАЗМУ'ЧАТЬ** *сов. устар.* — к. размучить.

**РАЗМУ'ЧАТЬСЯ** *сов. устар.* — к. размучиться.

**РАЗМУ'ЧИВАТЬ** *несов. устар.* — к. размучить.

**РАЗМУ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. устар.* — к. размучиться.

**РАЗМУ'ЧИТЬ** *сов. устар.* — артык җәфалау, бик нык интектерү, газаплап (җәфалап) бетерү; йөдәтеп бетерү.

**РАЗМУ'ЧИТЬСЯ** *сов. устар.* — җәфаланып бетү, интегеп бетү, газапланып (йөдәп) бетү.

**РАЗМЫ'В** *м.* — **1.** *только. ед.* к. размыть, размыться; **2.** к. размоина.

**РАЗМЫВА'НИЕ** *ср. мн.* нет — **1.** к. размывать; **2.** *геол.* су белән җимерелү, юылу, ашалу; судан ишелү (мәсәлән, яр).

**РАЗМЫВА'ТЕЛЬ** *м. тех.* — юдыргыч, юдыру җайланмасы; *размыватель золы* —

көл юдыргыч (пар казаннары астында жыела торган көлне су белән юдырып төшерә торган җайланма).

**РАЗМЫВА'ТЬ** *несов.*— к. размыть.

**РАЗМЫВА'ТЬСЯ** *несов.*—1. к. размыться; 2. *страд.* (су белән) юылу, ашалу, җимерелү, ишелү, казылу.

**РАЗМЫ'ВЧАТЫЙ** *обл.* — судан ашала (ишелә, җимерелә) торган; ашалучан, ишелүчән; *размывчатый берег* — (судан) ишелә торган яр.

**РАЗМЫКА'ТЕЛЬ** *м. тех.*— өзгеч (электр тогын өзә торган җайланма).

**РАЗМЫ'КАТЬ** *сов. разг. нар.-поэт.*— 1. тарату, күңелдән чыгару, әкренләп оныту, оныта бару; *размыкать горе* —кайгыны әкренләп оныту; 2. кангырып йөреп үткәрү, гидай (сукбай) булып йөрү; авыр тормыш кичерү; *лучшую пору моей жизни я размыкал по губернским городам* (Салтыков-Щедрин) — тормышымның иң матур чагын мин губерна шәһәрләрендә кангырып йөреп үткәрдем.

**РАЗМЫКА'ТЬ** *несов.*— к. разомкнуть.

**РАЗМЫКА'ТЬСЯ** *сов. разг. нар.-поэт.*— әкренләп онытылу, күңелдән чыгу, таралу (мәсәлән, кайгы).

**РАЗМЫКА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. разомкнуться; 2. *страд.* ачып куелу, өзеп куелу; ара ачылу, ара киңәйтелү.

**РАЗМЫ'КИВАТЬ** *несов. разг. нар.-поэт.* — к. размыкать.

**РАЗМЫ'КИВАТЬСЯ** *несов. разг. нар-поэт.*— к. размыкаться.

**РАЗМЫ'СЛИТЬ** *сов. разг.*—фикер йөртү, уйлап карау, исәпләп (чамалап) карау.

**РАЗМЫ'СЛИТЬСЯ** *сов. разг.* — уйлану, уйга бату, уйга бирелү (чуму).

**РАЗМЫ'ТЬ** *сов.*— 1. юу, ашау, (юып) җимерү, ишү; *река размыла берег* — су елганың ярын ашаган (елганың бер як яры ашалган); 2. еру, алып китү, юып китү (мәсәлән, буаны).

**РАЗМЫ'ТЬСЯ** *сов.*—юылу, ашалу, ишелү, җимерелү (мәсәлән, елга яры).

**РАЗМЫ'ЧКА** *ж. мн.* нет — 1. *спец.* к. разомкнуть; 2. *перен. разг.* элемтә өзелү, элемтәне югалту, бәйләнешне югалту.

**РАЗМЫШЛЕ'НИЕ** *ср.*— 1. *только ед.* к. размышлять; 2. уй, фикер; *погрузиться в размышления* — уйга бату.

**РАЗМЫШЛЯ'ТЬ** *несов.* — 1. к. размыслить; 2. уйлау, уйлану, уйга чуму; фикер йөртү; *размышлять о законах природы* — табигать законнары турында фикер йөртү.

**РАЗМЯГЧА'ТЬ** *несов.*— к. размягчить.

**РАЗМЯГЧА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. размягчиться; 2. *страд.* йомшартылу, йомшатылу

**РАЗМЯГЧЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книжн.*— 1. к. размягчить, размягчиться; *размягчение костей* — сөякләрнең йомшавы; 2. күңел йомшару, шәфкатьле (мәрхәмәтле) булу.

**РАЗМЯГЧИ'ТЕЛЬНЫЙ** *спец.*— йомшарта торган, йомшарткыч; *размягчительный пластырь* — йомшарта торган пластырь (йомшарткыч пластырь).

**РАЗМЯГЧИ'ТЬ** *сов.* — 1. йомшату, йомшарту; *размягчить кожу*—күнне йомшарту; 2. *перен. книжн.* күңелне йомшарту, күңелне эретү.

**РАЗМЯГЧИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. йомшау, йомшару; йомшарып китү; *кожа размягчилась* —күн йомшарган; 2. *перен* (күңел) йомшару, эрү; шәфкате (мәрхәмәте) килү; *сердце размягчилось, и гнев прошёл* — күңеле йомшарды, һәм ачуы да бетте.

**РАЗМЯКА'ТЬ** *несов.*— к. размякнуть.

**РАЗМЯ'КЛЫЙ** *обл.* — йомшарган, изелгән, җебегән, изрәгән.

**РАЗМЯ'КНУТЬ** *сов.*— 1. йомшау, йомшару, җебү, изелү, изрәү; *сухари размякли в воде* — сохари суда җебегән; 2. *перен. фам. пренебр.* җебеп төшү, изрәп китү, күңеле артык йомшарып китү.

**РАЗМЯ'ТЬ** *сов.*— 1. йомшарту, уып(угалап) йомша(р)ту; *размять кожу* — күнне угалап йомшарту; 2. яхшылап изү, изеп үзеләндерү; *размять глину* — балчыкны изеп үзеләндерү; 3. *перен. разг* оерга бирмәү, яз(ылдыр)у; *размять ноги* — аякларны язу; 4. *перен. разг.* йөртү, йөртеп алу.

**РАЗМЯ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. йомшау, йомшару; *кожа размялась* — күн йомшарган; 2. изелү, үзеләнү; *глина размялась* — балчык үзеләнгән; 3. *разг. фам.* (йөреп, хәрәкәтләнеп, аяк-кулларны) язу; язылу.

**РАЗНАЙТО'ВИТЬ** *сов. мор.*— бауларын чишеп алу (мәсәлән, мачтаның).

**РАЗНАРЯ'ДКА** *ж. спец.* — разнарядка, исемлек (мәсәлән, материал бүлеп бирү өчен).

**РАЗНА'ШИВАТЬ** I *несов.*—к. разносить I.

**РАЗНА'ШИВАТЬ** II *несов. просторечь.*— к. разнести 1, 2, 3.

**РАЗНА'ШИВАТЬСЯ** I *несов.*— 1. к. разноситься I; 2. *страд.* киеп иркенәйтелү, киякия җәелү (аякка ипләнү).

**РАЗНА'ШИВАТЬСЯ** II — *несов. страд. просторечь.* — таратылу, йөреп таратылу, таратып чыгылу (мәсәлән, хат).

**РАЗНЕДУ'ЖИТЬСЯ** *сов. обл.*— к. разнемочься.

**РАЗНЕ'ЖИВАТЬ** *несов. разг.*— к. разнежить.

**РАЗНЕ'ЖИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— 1. к. разнежиться; 2. *страд.* артык иркәләп (назлап) бозылу.

**РАЗНЕ'ЖИТЬ** *сов. разг.* — 1. назланып күңелен йомшарту, назланып күңелен нечкәртү; иркәләнеп күңелен йомшарту, иркәләнеп җәлләтү, кызгандыру; *ребёнок разнежил родителей* — бала иркәләнеп атаанасының күңелен йомшартты; 2. иркәләп бетерү, иркәләп бозу.

**РАЗНЕ'ЖИТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. (*расчувствоваться*) күңел йомшару, күңел нечкәрү; нечкә күңелләнеп китү; 2. иркәләнеп (рәхәтләнеп, хозурланып) яту; *разнежиться в постели* — урында рәхәтләнеп яту.

**РАЗНЕ'ЖНИЧАТЬСЯ** *сов. разг.*— артык иркәлә(н)ү, артык назла(н)у; артык иркәләнеп китү; назла(ны)п сөйләшү.

**РАЗНЕМОГА'ТЬСЯ** *несов. просторечь.* — к. разнемочься.

**РАЗНЕМО'ЧЬСЯ** *сов. просторечь.*— нык

авырый башлау, авырып (сырхап, хасталанып) китү.

**РАЗНЕСТИ'** *сов.*— 1. (йөреп) тарату, таратып (өләшеп) чыгу; таратып бетерү; *разнести письма по адресам* — хатларны адреслары буенча таратып чыгу; 2. теркәү, язып чыгу, теркәп чыгу; *разнести сведения на карточки* — мәгълүматларны карточкаларга язып чыгу; 3. *перен.* хәбәр тарату, гайбәт чәчү; 4. *перен. разг.* вату, җимерү; туздыру; тар-мар итү; *крестьяне разнесли помещичьи усадьбы* — крестьяннар алпавыт утарларын туздырдылар; 5. *разг.* тарату, таратып (туздырып, куып) җибәрү; *ветер разнёс тучи* — җил болытларны таратты; 6. *безл. перен. простореч.* тулылану, тулыланып китү, симерү, җәелү; кабару, шешү, шешеп китү; *щеку разнесло* — янагы шешеп киткән; *иной бы с горя зачах, а тебя ещё разнесло* (Тургенев) — бер кеше булса кайгысыннан ябыгып бетәр иде, ә син тагы да тулыланып киткәнсең; 7. *перен. разг. фам.* орышып (әрләп, сүгеп, тиргәп) ташлау; тетеп салу; *вы, конечно, разнесёте меня* (Горький) — сез, билгеле, мине тетеп салырсыз. ◇ **Разнести в пух и в прах** — пыр туздыру, пыран-заран китерү, тетмәсен тетү, измәсен изү, тар-мар итү.

**РАЗНЕСТИ'СЬ** *сов.*— 1. (бик тиз) таралу, җәелү, телгә керү; *разнеслись слухи* — хәбәрләр таралды; 2. (*о звуке*) яңгырау, кинәт яңгырап китү, яңгырап ишетелү.

**РАЗНИЗА'ТЬ** *сов.*—1. җепкә тезгәнне тарату, җебен чыгару; *разнизать бусы* — муенсаның җебен чыгару; 2. *простореч.* артык күп тезеп чыгу, бик күп тезеп бизәү.

**РАЗНИЗА'ТЬСЯ** *сов.* — чәчелү, сибелү, җебеннән чыгу (мәсәлән, җепкә тезгән әйбер турында).

**РАЗНИ'ЗЫВАТЬ** *несов.*— к. разнизать.

**РАЗНИ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. разнизаться; 2. *страд.* җебеннән алыну, җебеннән чыгарылу.

**РАЗНИМА'ТЬ** *несов.*— к. разнять.

**РАЗНИМА'ТЬСЯ** *несов.* — к. разняться.

**РА'ЗНИТЬСЯ** *несов. книж.* — (бер-берсеннән) аерылу, аерылып тору, аермалы булу; үзгә булу, башка булу.

**РА'ЗНИЦА** *ж. мн.* нет — аерма, башкалык, үзгәлек, аермалык. ◇ **Большая разница**; *разг. фам.*— бөтенләй башка (ча). **Какая разница?** *разг. фам.*— барыбер түгелмени?

**РА'ЗНО** *нареч. разг.* — төрлечә, төрле рәвештә; башкача, үзгәчә; *об этом можно думать разно* — бу турыда төрлечә уйларга мөмкин.

**РАЗНОБО'Й** *м. мн.* нет — 1. *спец.* (*разные битые вещи*) һәртөрле ватык-сынык, ватык-җимерек; 2. *разг.* (фикердә, эштә һ. б.) төрлелек, аерымлык, башкалык; каршылык (лар); *разнобой в правописании* — орфографиядәге төрлелек; *разнобой в работе* — эштәге каршылыклар.

**РАЗНОВЕ'С** *м. мн.* нет, *торг.* — вак герләр, вак үлчәүлекләр.

**РАЗНОВЕ'СКА** *ж.*, **РАЗНОВЕ'СОК** *м.* *спец. торг.*— кечкенә гер (вак герләрнең берсе).

**РАЗНОВИ'ДНОСТЬ** *ж. книж.*— 1. *биол.* (*группа внутри вида*) төрчә; *разновидность пшеницы* — бодайның төрчәсе (бодайның бер төре); 2. (*единичный представитель*) аерым вәкил, бер сынар (ягъни бер үсемлек яки хайван); 3. *перен.* (аерым) бер төр, (үзенә) бер төр, (үзенә) бер күренеш.

**РАЗНОВИДНЫЙ** *спец.* — төрле - төрле, һәр төрле.

**РАЗНОВРЕМЕ'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— төрле вакытка карага̀нлык, төрле вакытта (чорда) булганлык.

**РАЗНОВРЕМЕ'ННЫЙ** *книж.*— төрле вакыттагы, төрле заманга караган, төрле вакытта булган; *разновременные события* — төрле вакытта булган вакыйгалар.

**РАЗНОВЫСО'КИЙ** *спец. спорт.*— төрле биеклектәге; *разновысокие параллельные брусья* — төрле биеклектәге параллель борыслар.

**РАЗНОГЛА'ЗЫЙ** *разг.*— 1. төрле күзле, төрле төстәге күзле (күзләре ике төстә булган); 2. *простореч.* кылый күзле.

**РАЗНОГЛА'СИЕ** *ср.*— 1. *книж. устар. муз.* көйсезлек, тәэсексезлек, аһәңсезлек, тавыш төрлелеге (җырда яки музыка коралында); 2. фикер аерымлыгы, фикер башкалыгы; каршылык, бердәмлек булмау; *разногласия между капиталистическими странами* — капиталистик илләр арасындагы каршылыклар; 3. капма-каршылык, төрлечә сөйләү, туры килмәү, ярашмау; *разногласие в показаниях свидетелей* — шаһитларның күрсәтүләрендәге капма-каршылык.

**РАЗНОГЛА'СИТЬ** *несов. книж. устар.*— 1. килешмәү, ризалашмау, риза булмау, башка фикердә булу; 2. каршылыклы булу, капма-каршы булу, туры килмәү, төрлечә булу; *показания свидетелей разногласили* — шаһитларның күрсәтүләре капма-каршы иде.

**РАЗНОГЛА'СНЫЙ** *книж. устар.*—1. көйсез, көйгә салынмаган; аһәңсез, төрле тавышлы (музыка яки җыр); 2. (*несогласный*) каршылыклы, капма - каршылыклы, төрле фикерле.

**РАЗНОГОЛО'СИЦА** *ж. мн.* нет —1. *разг.* (*нестройное пение*) көйсезлек, төрлесе төрлечә җырлау (акыру); 2. (*разногласие*) төрле фикер, фикер башкалыгы, фикер каршылыгы.

**РАЗНОГОЛО'СЫЙ** — 1. *разг.* көйсез, аһәңсез, төрлесе төрлечә...; *разноголосое пение* — төрлесе төрлечә җырлау; 2. төрле тавышлы, төрлечә кычкыра (яңгырый) торган; төрле тавыш белән...; *слышно разноголосое пение птиц* (Чехов) — кошларның төрле тавыш белән сайраулары ишетелә.

**РАЗНОДО'МНЫЕ** *ср. ед.* нет, *бот.*— төрле өйлеләр (берсендә аналык чәчәкләре, икенчесендә аталык чәчәкләре була торган үсемлекләр).

**РАЗНО'ЖКА** *ж. спорт.*— аякларны ае-

рып сикерү, җәеп сикерү (махсус спорт җайланмасы аша).

**РАЗНОЗНА'ЧАЩИЙ** *книж.* — к. разнозначный.

**РАЗНОЗНА'ЧНЫЙ** *книж.* — 1. төрле дәрәҗәдәге, төрле-төрле; төрле мәгънәле; әһәмияте (кыйммәте) төрле булган.

**РАЗНОИМЕННЫЙ** *книж.* — төрле исемдәге, төрле тамгалы; *разноимённые виды* — төрле исемдәге төрләр; *разноимённые электрические заряды* — төрле тамгалы электр корылмалары.

**РАЗНОКАЛИ'БЕРНЫЙ** — 1. *спец.* төрле калиберлы, төрле калибердагы, калиберы башка булган; 2. *перен. разг.* төрле зурлыктагы, төрле күләмдәге, төрле үлчәүле, төрле формалы; *разнокалиберная посуда* — төрле зурлыктагы савыт-саба; 3. *перен. разг.* төрле-төрле, һәртөрле, катнаш, аралаш, чуар; *разнокалиберная толпа* — чуар халык төркеме.

**РАЗНОЛИ'КИЙ** *устар. ритор.* — төрле кыяфәтле; төрле-төрле, һәртөрле

**РАЗНОЛИ'СТНЫЙ** *бот.* — төрле яфраклы, төрле формадагы яфраклы (үсемлек).

**РАЗНОЛОСКУ'ТНЫЙ** — корама, кырык корамалы.

**РАЗНОМА'СТНЫЙ** — 1. (*о лошадях и т. п.*) төрле төсле, төрле төстәге; 2. (*о картах*) төрле мачлы, мач булмаган; 3. *перен.* һәртөрле, төрле-төрле, төрле ишле, төрле төрдәге.

**РАЗНОМЫ'СЛИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — фикер (караш) төрлелеге; төрле фикерлелек, төрле караш.

**РАЗНОМЫ'СЛЯЩИЙ** *книж.* — башка фикерле, башкача уйлаучы, каршы фикерле.

**РАЗНООБРА'ЗИЕ** *ср. мн.* нет — төрлелек, төрлечәлек, төрле-төрле булу; *разнообразие впечатлений* — тәэсирләрнең төрле-төрле булуы; *для разнообразия* — төрлелек өчен.

**РАЗНООБРА'ЗИТЬ** *несов.* — төрлеләндерү, төрле-төрле итү; төрлелек кертү, төрле төскә кертү.

**РАЗНООБРА'ЗИТЬСЯ** *несов.* — 1. төрлеләнү; 2. *страд.* төрлеләндерелү, төрлелек кертелү.

**РАЗНООБРА'ЗНО** *нареч.* — төрлечә (итеп), төрле рәвештә, төрле төстә; *разнообразно проводить время* — вакытны төрлечә үткәрү.

**РАЗНООБРА'ЗНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — к. разнообразие.

**РАЗНООБРА'ЗНЫЙ** — төрле, төрле-төрле, төрле рәвешле, һәртөрле; *разнообразные впечатления* — төрле-төрле тәэсирләр.

**РАЗНОПЛЕМЁННЫЙ** *книж.* — 1. төрле кабиләле, күп милләтле; күп төрле кабиләләрдән (милләтләрдән) торган; *разноплемённое население древних государств* — борынгы дәүләтләрнең төрле кабиләләрдән гыйбарәт булган халкы; 2. *с.-х.* төрле нәселле, төрле токымлы; төрле нәселдән (токымнан) булган.

**РАЗНОРЕЧИ'ВО** *нареч.* — төрлечә, төрлесе төрлечә, каршылыклы итеп; *свидетели показывали разноречиво* — шаһитлар төрлечә сөйләделәр (каршылыклы мәгълүматлар бирделәр).

**РАЗНОРЕЧИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — туры килмәү, каршылыклы булу; *разноречивость сообщений* — хәбәрләрнең бер-берсенә туры килмәве (каршылыклы булуы).

**РАЗНОРЕЧИ'ВЫЙ** *книж.* — төрле-төрле, төрлечә; бер-берсенә туры килми торган; бер-берсенә каршы, каршылыклы; *разноречивые показания свидетелей* — шаһитларның төрлечә күрсәтүләре (сөйләүләре); *разноречивые слухи* — каршылыклы хәбәрләр.

**РАЗНОРЕ'ЧИЕ** *ср. книж.* — 1. (*разногласие*) каршылык, туры килмәү, төрлелек (сүздә, мәгънәдә); 2. *филол. устар.* (*говор*) сөйләш, шивә.

**РАЗНОРЕ'ЧИТЬ** *несов. книж. устар.* — төрлечә сөйләү, башкача сөйләү, капма-каршы сөйләү.

**РАЗНОРО'ДНЫЙ** *книж.* — 1. төрле, төрле-төрле; *разнородные явления* — төрле-төрле күренешләр; 2. төрле составлы; *разнородные вещества* — төрле составлы матдәләр; 3. төрле токымлы, төрле төрдән булган: *лошадь и корова* — *разнородные животные* — ат һәм сыер төрле токымнан булган хайваннар.

**РАЗНО'С** *м. разг.* — 1. *только ед.* к. разнести 1, 2, 4, 5, 7; 2. *фам.* каты шелтә, каты кисәтү; *не уберёгся от разноса* — каты шелтәдән котыла алмады; 3. *горн.* комташ карьеры (таш-ком чыгара торган урын). ◇ В разнос *торг.* — йөреп сату.

**РАЗНОСИ'ТЬ** I *сов.* — киеп иркенәйтү, киеп зурайту, киңәйтү; *разносить ботинки* — ботинканы киеп иркенәйтү.

**РАЗНОСИ'ТЬ** II *несов.* — 1. к. разнести; 2. таратып (өләшеп, илтеп) йөрү; *разносить письма* — хат таратып йөрү.

**РАЗНОСИ'ТЬСЯ** I *сов.* — кия-кия иркенәю (киңәю, зураю, ипләнү); бераз кигәч киңәеп чак (таман) булып калу; *сапоги разносились* — күн итек кия торгач киңәеп таман булды.

**РАЗНОСИ'ТЬСЯ** II *несов.* — 1. к. разнестись; 2. *страд.* (төрле урынга) таратылу, таратып (өләшеп) чыгылу; илтеп куелу; 3. *страд.* таратып язып куелу, теркәлү, урнаштырып чыгылу (мәс., саннар, мәгълүматлар); 4. *страд.* таратылу (мәс., сүз, хәбәр).

**РАЗНО'СКА** *ж. простореч.* — к. разнести 1, 2 һәм разносить II.

**РАЗНОСКЛОНЯ'ЕМЫЙ** *грам.* — төрлечә төрләнешле; *разносклоняемые слова* — төрлечә төрләнешле сүзләр (төп төрләнешләр буенча төрләнми торган сүзләр).

**РАЗНОСЛО'ЖНЫЙ** *лит. лингв.* — иҗек саны төрлечә булган; *разносложные стихи* — иҗек саны төрлечә булган шигырьләр.

**РАЗНО'СНЫЙ** *спец.* — 1. *торг.* йөреп..., йөреп сатыла торган; *разносная торговля* — йөреп сату; *разносный товар* — йөреп сатыла торган товар; 2. *разг. фам.* бик каты, җимергеч, юкка чыгара торган, тетмәсен теткән; *разносная рецензия* — җимергеч рецензия; 3. *разг.* тиргәүле, әрләү-

ле; сүгенү (орышу)...-ы; *разносные слова* — орышу сүзләре. ◇ Разносная книга *канц.* — теркәп тарату кенәгәсе (бер оешмадан чыгып китә торган рәсми хат һәм кәгазьләрне теркәп таратып йөрү өчен махсус дәфтәр).

**РАЗНОСО'Л** *м.* — 1. *кулин.* тозланмалар (төрлечә тозланган яки серкәдә тотылган яшелчә, җимеш һ.б.); 2. *кулин.* (ашка) тәм керткечләр, тәмләткечләр; 3. *чаще мн. разг. фам.* төрле-төрле тәмле азыклар, тансык азыклар, нәзакәтле азыклар.

**РАЗНОСОСЛО'ВНЫЙ** *истор.* — төрле сословиедән булган, төрле сословие...-ы; *разносословные представители* — төрле сословие вәкилләре.

**РАЗНОСОСТА'ВНЫЙ** *книж.* — төрле составлы, составы төрле булган, төрле матдәләрдән ясалган; *разносоставные мази* — төрле матдәләрдән ясалган мазьлар.

**РАЗНОСПО'РОВЫЕ** *ср.* — төрле споралылар (үсемлекләр).

**РАЗНОСПРЯГА'ЕМЫЙ** *грам.* — төрлечә төрләнә торган (фигыль).

**РА'ЗНОСТНЫЙ:** разностная (или арифметическая) прогрессия *мат.* — аермалы (яки арифметик) прогрессия; разностные тоны *физ.* — аерма тоннары.

**РАЗНОСТО'ПНЫЙ** *лит.* — төрле стопалы (шигырь юлларында стопа саннары төрле булган); *разностопный ямб* — төрле стопалы ямб.

**РАЗНОСТОРО'ННЕ** *нареч.* — һәрьяклап, һәр яктан, төрле яктан, киң рәвештә; *разносторонне образованный человек* — киң белемле кеше.

**РАЗНОСТОРО'ННИЙ** I *мат.* — төрле яклы, яклары тигез булмаган; *разносторонний треугольник* — төрле яклы өчпочмак.

**РАЗНОСТОРО'ННИЙ** II — 1. күпьяклы, күпкырлы, төрле-төрле; *разносторонние взгляды* — күпьяклы карашлар; *разносторонняя деятельность* — күпкырлы эшчәнлек; 2. киң карашлы, күп белемле, киң мәгълүматлы; һәр яктан сәләтле; күп нәрсә белән кызыксынучан; *разносторонний человек* — киң мәгълүматлы кеше.

**РАЗНОСТОРО'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. *мат.* төрле яклылык (яклары тигез булмау); 2. күпьяклылык, күпьяклы булу, киң кырлылык; *разносторонность деятельности* — эшчәнлекнең күпьяклы булуы; 3. (*о кругозоре*) киң белемле булу, киң мәгълүматлы булу, киң карашлылык.

**РА'ЗНОСТЬ** *ж.* — 1. *мат.* аерма; *разность двух чисел* — ике санның аермасы (алганнан соң калдыгы); 2. *мн.* нет, *книж.* аерымлык, башкалык; *разность взглядов* — карашларының башкалыгы; *разность характеров* — холыкларының аерымлыгы. ◇ Разные разности *разг. фам.* — төрле-төрле нәрсәләр, җыен вак-төяк нәрсәләр.

**РАЗНО'СЧИК** *м.*, **РАЗНО'СЧИЦА** *ж.* — 1. таратучы, өләшүче, таратып йөрүче; *разносчик газет* — газета таратучы; 2. (йөреп) сатучы; сатып йөрүче; *разносчик мороженого* — мороженый сатучы; 3. *устар.* (*коробейник*) кырык тартмачы, асламчы (вак-төяк товар сатучы).

**РАЗНОТРА'ВЬЕ** *собир.* — төрле үләннәр.

**РАЗНОТРА'ВНЫЙ** *спец.* — төрле үләнле, төрле үләннәрдән торган; *разнотравное сено* — төрле үләннәрдән торган печән.

**РАЗНОХАРА'КТЕРНЫЙ** *книж.* — төрле характердагы, төрле-төрле, төрле төрдәге, төрле составлы.

**РАЗНОЦВЕ'ТНЫЙ** — төрле төстәге, аллы-гөлле; *разноцветные ткани* — төрле-төрле төстәге тукымалар; *разноцветная радуга* — аллы-гөлле салават күпере.

**РАЗНОЧИ'НЕЦ** *м. истор.* — разночин, разночин интеллигент (XIX йөздә Россиядә дворяннар сыйныфыннан түгел, бәлки бүтән сословиеләрдән, игъни, сәүдәгәрләр, руханилар, чиновниклар, мещаннар һәм крестьяннар арасыннан чыккан интеллигентлар); *писатели-разночинцы* — разночин язучылар.

**РАЗНОЧИ'ННЫЙ** *истор.* — разночин..., төрле катлау...; *разночинные интеллигенты* — разночин интеллигентлар.

**РАЗНОЧТЕ'НИЕ** *ср. филол.* — вариант, төрлелек (берәр әдәби әсәрнең төрле нөсхәләрендә төрлечә язылган урын).

**РАЗНОШЁРСТНЫЙ** — 1. *спец.* төрле төстәге, төрле төстәге йонлы; *разношёрстные лошади* — төрле төстәге атлар; 2. *перен.* һәргерле, төрле-төрле, чуар; *разношёрстная публика* — чуар публика.

**РАЗНОЯЗЫ'ЧИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — төрле теллелек, төрле телдә сөйләшү; телләрнең төрлелеге.

**РАЗНОЯЗЫ'ЧНЫЙ** *книж.* — 1. төрле телле; төрле телләрдә сөйләшә торган; *разноязычное государство* — халыклары төрле телләрдә сөйләшә торган дәүләт; 2. төрле телләр...-ы; төрле тел сүзләреннән төзелгән; *разноязычный словарь* — төрле телләр сүзлеге.

**РА'ЗНСТВОВАТЬ** *несов. книж. устар.* — аерылу, аерылып тору.

**РАЗНУ'ЗДАННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. (*распутство*) азгынлык, бозыклык, әхлаксызлык; азу-тузу; 2. (*произвол*) башбаштаклык, чиктән тыш котырганлык, йөгәнсезлек.

**РАЗНУ'ЗДАННЫЙ** — 1. авызлыксыз, авызлыгы алынган (ычкындырылган, салдырылган); *разнузданная лошадь* — авызлыгы салдырылган ат; 2. *перен. неодобр.* азган-тузган, бозык, әхлаксыз; *разнузданный образ жизни* — бозык тормыш алып бару; 3. *перен. неодобр.* чиктән тыш котырынган, башбаштак, тыелгысыз, йөгәнсез; *разнузданная империалистическая пропаганда* — империалистларның котырынган пропагандасы.

**РАЗНУЗДА'ТЬ** *сов.* — 1. авызлыгын салдыру (ычкындыру, алу); *разнуздать лошадь* — атның авызлыгын салдыру; 2. *перен. неодобр.* артык ирек бирү, артык юл кую, артык үз иркенә кую; *разнуздать свои страсти* — үз дәртләренә артык ирек кую.

**РАЗНУЗДА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. авызлыгы ычкыну (салыну); *конь разнуздался* — ат-

ның авызлыгы ычкынган, ат авызлыгын салган; 2. *перен. разг. неодобр.* азу, азу-тузу, азып (бозылып) китү; начар юлга басу, бозыклыкка бирелү; йөгәнсезләнеп китү, тыйнаксызлану.

**РАЗНУ'ЗДЫВАТЬ** *несов.* — к. разнуздать.

**РАЗНУ'ЗДЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. разнуздаться; 2. *страд.* авызлыгы салдырылу (алыну, ычкындырылу).

**РА'ЗНЫЙ** — 1. төрле, төрле-төрле; башка төрле; *они разные люди* — алар төрле-төрле кешеләр; 2. аерым, аерым-аерым, башка-башка, үзенә башка; *эти вещи разные* — болар һәркайсы үзенә башка нәрсә; 3. *мн.* һәртөрле, төрле-төрле, күп төрле, төрле ...-дан җыелган; *букет из разных цветов* — төрле чәчәкләрдән җыелган букет; 4. *разг. пренебр.* һәртөрле, җыен, әллә нинди; *разный хлам* — җыен чүп-чар. ◇ **Разное** *в знач. сущ.* — төрлеләр (көн тәртибендә).

**РАЗНЮ'ХАТЬ** *сов. разг.* — 1. исеннән белү, иснә(не)п белү, исе буенча табу; 2. *перен. фам.* серен ачу; эзенә төшү, астыртын тикшереп белү; *я это дело разнюхаю* — мин бу эшнең эзенә төшәрмен.

**РАЗНЮ'ХИВАТЬ** *несов. разг.* — 1. к. разнюхать; 2. иснәнү, иснәп (иснәнеп) тору.

**РАЗНЯ'ТЬ** *сов.* — 1. *спец.* сүтү, тарату, сүтеп ташлау; кисәкләргә тарату; *разнять машину для чистки* — машинаны чистарту өчен сүтү; 2. *перен. разг.* (бер-берсеннән) аеру, аерып кую; *разнять руки* — кулларын аеру; 3. *разг.* аеру, аерып алу, аралау; *разнять дерущихся* — сугышучыларны аралау.

**РАЗНЯ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. *спец.* сүтелү, кисәкләргә аерылу; *машина легко разнялась* — машина җиңел сүтелде; 2. бер-береннән аерылу, аерылып китү.

**РАЗОБИ'ДЕТЬ** *сов. разг.* — бик нык хәтерен калдыру, рәнҗетү; бик каты үпкәләтү.

**РАЗОБИ'ДЕТЬСЯ** *сов. разг.* — бик нык хәтере калу, үпкәләү; рәнҗү.

**РАЗОБИЖА'ТЬ** *несов. разг.* — к. разобидеть.

**РАЗОБЛАЧА'ТЬ** *несов.* — к. разоблачить.

**РАЗОБЛАЧА'ТЬСЯ** *несов.* — к. разоблачиться.

**РАЗОБЛАЧЕ'НИЕ** *ср.* — 1. к. разоблачить, разоблачиться; 2. гаебен ачучы, фаш итүче факт.

**РАЗОБЛАЧИ'ТЕЛЬ** *м. книж.* — фаш итүче, гаебен ачучы, серен ачучы.

**РАЗОБЛАЧИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — фаш итә торган, серен (гаебен) ача торган; *разоблачительная статья* — фаш итә торган мәкалә.

**РАЗОБЛАЧИ'ТЬ** *сов.* — 1. *церк.* (поплар, монахларның) гыйбадәт киемен салдыру, гыйбадәт киемен чишендерү; 2. *разг. шутл.* салдыру, чишендерү; өстен салдырып алу; 3. *перен.* фаш итү, гаебен ачу, серен ачу; йөзен ачу, битлеген ерту; *разоблачить происки поджигателей войны* — сугыш уты кабызучыларның астыртын эшләрен (мәкерле хәйләләрен) фаш итү.

**РАЗОБЛАЧИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. (*раскрыться*) фаш ителү, гаебе (сере, ялганы) ачылу; 2. *разг. шутл.* (*раздеться*) чишенү, өсне салу; 3. *церк.* гыйбадәт киемен салу, гыйбадәт киемен салып кую.

**РАЗОБРА'ТЬ** *сов.* — 1. сүтү, тарату; таратып (сүтеп) ташлау; кисәкләргә аеру; *разобрать машину* — машинаны сүтү; 2. *разг.* алып бетерү, сатып алып бетерү; *разобрать лопаты* — көрәкләрне алып бетерү; 3. тәртипләү, рәтләү, рәткә салу, тәртипкә салу, тәртипкә китерү; *разобрать скопившиеся бумаги* — җыелган кәгазьләрне тәртипкә салу; 4. *спец.* кулга алу, яхшылап (аерып) тоту (тезгенне, дилбегәне); 5. җентекләп тикшерү, тикшереп чыгу, җентекләп карау, карап чыгу; тикшереп ачыклау; *разобрать вопрос* — мәсьәләне җентекләп тикшерү; 6. *грам.* тикшерү, анализлау, анализ ясау; *разобрать предложение* — җөмләә тикшерү (җөмләгә анализ ясау); 7. тикшерү, тикшереп бәя бирү; *разобрать книгу* — китапны тикшереп бәя бирү; 8. *разг.* аеру, аера алу, тану; *разобрать почерк* — кулын аеру, язуын тану; 9. (сизү органнары ярдәмендә) аеру; 10. төшенү, аңлау, аңлап җиткерү; *не разобрал его вопроса* — соравын аңлап җиткермәдем; 11. *перен. простореч.* (*опьянить*) исертү, изрәтү, башка китү. ◇ **Разобрала зависть** — көнчелеге килде. **Разобрало сомнение** — шикә калды, шик-шөбһәгә төште. **Его разобрало чихнуть** — аның кинәт бик каты төчкерәсе килде. **Его разобрало ехать** — аның китәсе килә башлады. **Разобрать по косточкам** *кого-н.* — энәсеннән җебенәчә тикшереп чыгу (гайбәтен сату). **Не разбери-поймёшь** или **не разбери-бери** *простореч. фам.* — очына чыгарлык түгел (бик чуалчык, четерекле хәл турында).

**РАЗОБРА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. (*разняться по частям*) сүтелү; (кисәкләргә) аерылу, таралу; 2. *разг.* тәртипкә китерү, рәткә салу, (әйберләрне тәртипләп урнаштыру; *приехал, разобрался и лёг отдохнуть* — кайтып төшкәч, әйберләрен тәртипкә китергән дә ял итәргә яткан; 3. *разг.* аңлау, төшенү, төшенеп җитү; тикшереп белү, ачыклау; *разобраться в деле* — эшне тикшереп белү.

**РАЗОБЩА'ТЬ** *несов.* — к. разобщить.

**РАЗОБЩА'ТЬСЯ** *несов.* — к. разобщиться.

**РАЗОБЩЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — аралашмау, катнашмау; ара өзелгәнлек; бәйләнеш юклык; таркаулык; *организационная разобщённость* — организацион таркаулык; *жить в полной разобщённости* — бер дә аралашмый яшәү.

**РАЗОБЩЁННЫЙ** — 1. бер-береннән аерылган, өзелгән, бүленгән; 2. бәйләнешсез, бәгланышсыз; аерым, таркау; еракләшкан, читләшкән.

**РАЗОБЩИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж. спец.* — аера торган, өзә торган.

**РАЗОБЩИ'ТЬ** *сов.* — 1. (*отделить*) аеру, аерып кую; 2. *перен.* читләштерү, еракләштыру, араларын өзү, ара бозу; 3. бәйләнешне (бәгланышны) өзү; ара-

лашуны туктату; *наводнение разобщило город с окрестными деревнями* — ташу шәһәрнең әйләнә-тирәдәге авыллар белән бәйләнешен өзде; 4. *спец.* өзү; *разобщить провода* — электр чыбыкларын өзү.

**РАЗОБЩИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. аерылу, читләшү, ераклашу, катнашмый (аралашмый) башлау; бәйләнеш өзелү, бәйләныш бетү; 2. *спец.* (*разъединиться*) өзелү; өзелеп китү.

**РАЗОВРА'ТЬСЯ** *сов. просторе*ч. *фам.* — артык ялганлый (алдаша) башлау; ялганлауның (алдашуның) чигенә чыгу.

**РА'ЗОВЫЙ** *простореч.*: **разовый пропуск** — бер керерлек пропуск; **разовый тираж газеты** — газетаның бер көнлек тиражы.

**РАЗОГНА'ТЬ** *сов.* — 1. куу, куып тарату, куып җибәрү; куалап җибәрү; *разогнать собак* — этләрне куып җибәрү; 2. *перен.* куу, тарату; *царское правительство разогнало первую государственную думу* — патша хөкүмәте беренче дәүләт думасын куды (таратты); 3. *перен.* тузгыту, таратып бетерү, куып бетерү; *ветер разогнал тучи* — җил болытларны таратып бетерде; 4. *перен. разг.* тарату, күңелдән чыгарып ташлау; *разогнать печаль* — кайгыны тарату; 5. *разг.* (бик нык куып) чаптыру, кызулату, тизләтү; *разогнать лошадей* — атларны куып чаптыру; 6. *разг. фам.* җәю, таратып (сирәгәйтеп) җыю, сузу; *разогнать набор на две полосы* — наборны ике баганалык итеп (сирәгәйтеп) җыю.

**РАЗОГНА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — бик кызулатып җибәрү; бик шәп (тиз) бару, җилдәй очу; *разогнаться на велосипеде* — велосипедта бик кызу бару (җилдәй очу).

**РАЗОГНУ'ТЬ** *сов.* — 1. төзәйтү, турайту, язу, җәю; *разогнуть спину* — арканы турайту; 2. *разг.* ачу, ачып кую; *разогнуть книгу* — китапны ачып кую.

**РАЗОГНУ'ТЬСЯ** *сов.* — тураю, төзәю, язылу.

**РАЗОГОРЧА'ТЬ** *несов. разг. фам.* — к. разогорчить.

**РАЗОГОРЧИ'ТЬ** *сов. разг. фам.* — зур кайгыга төшерү, хәсрәткә калдыру, бик нык ачындыру.

**РАЗОГОРЧИ'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.* — бик нык кайгыру, хәсрәткә калу, кайгыга төшү, ачыну.

**РАЗОГРЕВА'ТЬ** *несов.* — к. разогреть. ◇ **Разогревать самовар** — самовар яңарту.

**РАЗОГРЕВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг.* к. разогреться; 2. *страд.* җылыту, кыздырылу, җылытып җибәрелү; (бераз) кайнарлап алыну.

**РАЗОГРЕ'ТЬ** *сов.* — 1. җылыту; кыздыру; *разогреть моторы* — моторларны җылыту; 2. *разг.* эсселәтү, кызыштыру, кыздырып җибәрү (тәнне); 3. яңадан җылыту, җылытып (кайнарлатып) алу; *разогреть суп* — ашны җылытып алу; 4. *перен. разг.* (күңелне) җылыту, йомшарту, эретү; җылы кертү; *разогреть сердце* — йөрәккә җылы кертү.

**РАЗОГРЕ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. кызу; артык җылыну; *моторы разогрелись* — моторлар кызган; 2. *разг.* эсселәп китү, җылынып китү (тән); тәнгә җылы йөгерү; 3. җылыну, җылынып җитү, кайнарлану; *суп разогрелся* — аш җылынып җитте.

**РАЗОДЕВА'ТЬ** *несов. разг.* — к. разодеть.

**РАЗОДЕВА'ТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. разодеться; 2. *страд.* купшы итеп киендерелү, киендерелү-ясандырылу.

**РАЗОДЕ'ТЫЙ** *разг.* — купшы киенгән, бик шәп киенгән, киенгән-ясанган.

**РАЗОДЕ'ТЬ** *сов. разг.* — матур (купшы) итеп киендерү, киендерү-ясандыру.

**РАЗОДЕ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — (бик шәп) киенү, купшы (бәйрәмчә) киенү, киенү-ясану; *разоделся во всё новое* — бөтенләй яңадан киенгән.

**РАЗОДОЛЖА'ТЬ** *несов. разг. ирон. шутл.* — к. разодолжить.

**РАЗОДОЛЖИ'ТЬ** *сов. разг. ирон. шутл.* — шаккатыру, аю хезмәте күрсәтү, шәп утырту; *ну и разодолжил он нас!* — ну шәп утыртты да соң ул безне!

**РАЗОДРА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. ертып (тетеп) ташлау; ертып бетерү; *разодрать письмо* — хатны ертып бетерү; 2. ерту, ертып чыгару, тишеп чыгару, умырып чыгару; *разодрать брюки* — чалбарны ертып чыгару.

**РАЗОДРА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. ертылу, ертылып китү; ертылып (тетелеп, өзгәләнеп) бетү; *занавеска разодралась пополам* — пәрдә урталай ертылды; 2. ертылып (тишелеп) чыгу; *брюки разодрались* — чалбар ертылып чыккан; 3. (*подраться*) кызып сугышу, сугышып китү.

**РАЗОЗЛИ'ТЬ** *сов.* — бик каты ачуландыру, усалландыру, бик нык ачуын китерү, ачуын кабарту.

**РАЗОЗЛИ'ТЬСЯ** *сов.* — бик нык ачулану, усаллану, җен ачуы килү, ачу кабару.

**РАЗОЙТИ'СЬ** *сов.* — 1. таралу, таралышу, таралып китү, таралып бетү; сибелү; *гости разошлись* — кунаклар таралды; *толпа разошлась* — халык төркеме таралышты; *тучи разошлись* — болытлар таралып бетте; 2. *перен.* бетү, югалу; язылу, тигезләнү; *морщины на лбу разошлись* — маңгай җыерчыклары язылды; 3. *простореч.* бетү, кайту; *опухоль разошлась* — шеш бетте, шеш кайтты; 4. *перен.* эрү, эреп бетү; *масло в каше разошлось* — боткада май эреде; 5. сатылып (таралып) бетү; *всё издание книги разошлось* — китапның бөтен басмасы таралып бетте (сатылып бетте); 6. *разг.* тотылып бетү; *деньги разошлись на разные мелочи* — акча вак-төяккә тотылып бетте; 7. икегә аерылу, тармаклану; аерылып (тармакланып) китү; *за деревней дорога разошлась* — авылны чыккач, юл икегә аерылды (тармакланды); 8. аймылышу, аймыл булу, очрашмау, күрмичә узып китү; *разойтись в темноте* — карангыда күрмичә узып китү (аймыл булу); 9. (*о супругах*) аерылу, аерылышу; (*о друзьях*) ара өзелү, бәйләнеш өзелү; 10. (фикер белән) килешмәү, ризалашмау, риза булмау; (фикерләр) туры килмәү, башка булу, башка караштa тору; *разойтись с докладчиком в мнениях* —

докладчының фикерләре белән килешмәү; 11. ачылып китү, ара ачылу, ярык зураю; *половицы разошлись* — сайгакларның арасы ачылган; 12. *разг.* бик тиз (шәп) бара башлау, зур тизлек алу, кызулау; *велосипед разошёлся под гору* — велосипед түбән таба бик тиз бара башлады; 13. *просторечь.* (сираз йөргәч) аяклар язылу, язылып китү; *шёл с трудом пока не разошёлся* — аякларым язылганчы бик авыр бардым; 14. *перен. (о буре и т. п.)* көчәеп китү, көчәйгәннән көчәю, чиктән тыш котыру; 15. кызып китү, дәртләнеп китү; *старик разошёлся, лучше молодых пляшет!* — карт кызып китте, яшьләрдән дә болайрак бии!

**РАЗО'К** *м. разг.* — 1. бер тапкыр, бер мәртәбә, бер кат; *разок-другой* — бер-ике мәртәбә; 2. чалт, шап берне (сугу турында).

**РАЗОЛГА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — чамадан тыш ялганлый (алдый) башлау; ялганлауның чигеннән чыгу.

**РА'ЗОМ** *нареч. разг.* — 1. берьюлы, бер тоташтан; бер утыруда, бер...-да; *прочесть всё разом* — барысын бер утыруда укып чыгу; 2. *(сразу, мгновенно)* бердән, шундук, кинәт, озакка сузмыйча; бик тиз, күз ачып йомганчы. ◇ **Разом густо, а разом пусто** — булганда бүредәй, булмаганда шүредәй (бер карасаң бик мул, икенче карасаң берни юк).

**РАЗО'МКНУТЫЙ** — 1. өзелгән; *разомкнутый ток* — өзелгән ток; 2. сирәкләтелгән, аралары сирәк; *разомкнутым строем двигать отряды* — отрядларны сирәкләтелгән сафлар белән алып бару.

**РАЗОМКНУ'ТЬ** *сов.* — 1. өзү; *разомкнуть ток* — токны өзү (электр агымын туктату); 2. ачу, ачып җибәрү; *разомкнуть ворота шлюза* — шлюз капкасын ачып җибәрү; 3. *воен.* сирәгәйтү, араны киңәйтү, араны ачу; *разомкнуть строй* — стройны сирәгәйтү; 4. *спец.* бәйдән ычкындыру; *разомкнуть собак* — этләрне бәйдән ычкындыру.

**РАЗОМКНУ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. өзелү, өзелеп китү; *цепь разомкнулась* — чылбыр өзелде; 2. ачылып китү, аерылып китү (ике якка); *дверцы разомкнулись* — ишек ике якка ачылып китте; 3. *воен. спорт.* (ара калдырып) җәелү; ара ачылу, сирәкләнү.

**РАЗОМЛЕВА'ТЬ** *несов. разг.* — к. разомлеть.

**РАЗОМЛЕ'ТЬ** *сов. разг.* — хәлсезләнү, хәлдән таю, әлсерәү; әлсерәп (изрәп) төшү.

**РАЗОПРЕВА'ТЬ** *несов.* — к. разопреть.

**РАЗОПРЕ'ЛЫЙ** *просторечь.* — 1. парланып йомшарган; парланып пешкән (үз бушында); 2. тирләп пешкән, әлсерәгән, изрәгән.

**РАЗОПРЕ'ТЬ** *сов.* — 1. (үз парында, бушында) пешеп җитү, йомшау; *каша разопрела* — ботка үз парында пешеп җитте; 2. *просторечь. фам.* эсседән тирләп пешү, изрәп төшү; тирләп әлсерәү, хәлсезләнү; *от солнца совсем разопрел* — кояш кызуыннан тирләп пештем.

**РАЗО'Р** *м. просторечь.* — к. разорение.

**РАЗОРА'ТЬСЯ** *сов. просторечь.* — кычкырыну, акыра башлау, кычкырына башлау, озак акырыну, бугаз киерү.

**РАЗО'РВАННЫЙ** — 1. ертык, ертылган; 2. *перен.* өзек-өзек, таркау, бәйләнешсез; *разорванные фразы* — өзек-өзек җөмләләр.

**РАЗОРВА'ТЬ** *сов.* — 1. ерту, ертып чыгару, ертып бетерү, умырып чыгару (алу); *разорвать письмо на мелкие клочки* — хатны вак кисәкләргә ертып ташлау; 2. *перен.* ботарлау, ботарлап ташлау, ботарлап үтерү; *волк разорвал овцу* — бүре сарыкны ботарлап ташлаган; 3. өзеп ташлау, җимерү, вату, юк итү; *народ разорвал оковы царьи* (Маяковский)— халык патша богауларын өзеп ташлады; 4. *безл.* шартлату; *котёл разорвало* — казан шартлады (нәрсәдәндер), казанны шартлатты (нәрсәдер); 5. *перен.* араны (дуслыкны, бәйләнешне) өзү; туктату; *разорвать дипломатические переговоры* — дипломатик сөйләшүләрне туктату (өзү); *разорвать связи* — араны өзү, бәйләнешне өзү. ◇ **Разорвать на части** *разг. перен.* — теңкәгә тию, тынгылык бирмәү, тәкатен корыту. **Чтоб тебя разорвало** *просторечь. перен.* — кадалгыры, чәнчелеп киткере.

**РАЗОРВА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. ертылу, ертылып китү, ертылып чыгу; *одежда разорвалась* — кием ертылып китте; 2. ярылу, шартлау; *котёл разорвался* — казан шартлады (ярылды). ◇ **Я не могу разорваться** *разг. фам.* — мин кырыкка ярыла алмыйм (ягъни барысына да өлгерә алмыйм). ◇ **Хоть разорвись** *разг.* — теләсәң ярылып үл (эш күп булып, барысына да өлгерә алмаганда әйтелә).

**РАЗОРЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. к. разорить, разориться; 2. бөлгенлек, талану.

**РАЗОРИ'ТЕЛЬ** *м.* — бөлдерүче, бөлгенлеккә төшерүче, җимерүче, талаучы; таркатучы, харап итүче, туздыручы.

**РАЗОРИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книжн.* — бөлдергеч булу.

**РАЗОРИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книжн.* — бөлдергеч, бөлдерә торган, зарарлы, зарар (зыян) китерә торган.

**РАЗОРИ'ТЬ** *сов.* — 1. бөлдерү, бөлгенлеккә төшерү; хәерчеләндерү; *империалистическая война разорила трудящихся воюющих стран* — империалистик сугыш сугышучы илләрнең хезмәт ияләрен бөлгенлеккә төшерде; 2. җимерү, туздыру; тармар китерү; талау, таркату, вәйран итү; хәрабәләргә әйләндерү; *разорить гнездо* — ояны туздыру.

**РАЗОРИ'ТЬСЯ** *сов.* — бөлү, бөлеп бетү, бөлгенлеккә төшү, хәерчеләнү.

**РАЗОРУЖА'ТЬ** *несов.* — к. разоружить.

**РАЗОРУЖА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. разоружиться; 2. *страд.* коралсызландырылу.

**РАЗОРУЖЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. коралсызландыру; *разоружение пленных* — әсирләрне коралсызландыру; 2. коралсызлану; *частичное разоружение* — өлешчә коралсызлану; *всеобщее разоружение* — гомуми коралсызлану.

**РАЗОРУЖИ'ТЬ** *сов.* — 1. *воен.* коралсызландыру, коралын алу; *разоружить от-*

*ряд* — отрядны коралсызландыру; 2. *полит.* коралсызландыру, кораллануны кыскарту; 3. *воен.* орудиеләрне алу (крепостьтан, ныгытмадан); 4. *мор.* мачталарны сүтеп алу, мачта корылмаларын сүтеп алу; *разоружить судно* — корабльнең мачталарын алу; 5. *перен. книж.* коралсызландыру; көрәшү ихтыярын (омтылышын, мөмкинлеген) бетерү; *соглашатели стремились идейно разоружить пролетариат* — соглашательләр пролетариатны идея ягыннан коралсызландырырга омтылдылар.

**РАЗОРУЖИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *воен.* коралсызлану, корал ташлау; 2. *полит.* коралсызлану (тулы яки өлешчә); 3. *перен. книж.* корал ташлау, көрәштән ваз кичү, көрәшне туктату.

**РАЗОРЯ'ТЬ** *несов.* — к. разорить.

**РАЗОРЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. разориться; 2. *страд.* бөлдерелү, бөлгенлеккә төшерелү, хәерчеләндерелү; жимерелү, талану, туздырылу; жимереклекләргә (хәрабәләргә) әйләндерелү; 3. *перен. простореч.* кычкырыну, даулашу, чәпчү, тавыш куптару.

**РАЗОСЛА'ТЬ** *сов.* — 1. (төрле җиргә) җибәрү, тарату; *разослать письма* — хатлар җибәрү; 2. (һәммәсен) җибәреп бетерү, таратып бетерү; (барысын да) чыгарып җибәрү (эшкә); *разослать всех курьеров* — барлык курьерларны (йомыш белән) чыгарып җибәрү.

**РАЗОСПА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — (каты йокыга китеп) озак йоклау, бик күп йоклау.

**РАЗОСТЛА'ТЬ** *сов.* — 1. җәю, түшәү; җәеп кую, җәеп салу; *разостлать ковёр* — келәм җәю; 2. *перен. книж.* киң җәю, киң җәеп җибәрү; *дерево далеко разостлало свои ветви* — агач үзенең ботакларын киң җәеп җибәргән.

**РАЗОСТЛА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *простореч.* җәелү, түшәлү, җәеп салыну; (мәйданны) алу, иңләп алу; *ковёр разостлался по всему полу* — палас бөтен идәнгә җәелде (бөтен идәнне алды); 2. җәелү, басу, каплап алу; *туман разостлался по земле* — җир өстен томан каплап алды.

**РАЗОТКА'ТЬ** *сов. спец.* — нәкышьләп туку, бизәп туку, бизәк кертеп туку.

**РАЗОТКРОВЕ'ННИЧАТЬСЯ** *сов. разг. неодобр.* — ачыктан-ачык сөйләшә башлау, артык ачылып китү; бөтен эч серләрен сөйләп ташлау, бушатып ташлау.

**РАЗОХО'ТИТЬ** *сов. разг.* — теләк уяту; дәртләндерү, җилкендерү;...-сыны китерү; *разохотить к еде* — ашыйсыны китерү.

**РАЗОХО'ТИТЬСЯ** *сов. разг.* — теләк уяну; дәртләнеп китү, һәвәсләнеп китү, җилкенеп китү, кызып китү;...-сы килү; *разохотился и принялся играть* — кызып китте дә уйный башлады.

**РАЗОХО'ЧИВАТЬ** *несов. разг. редко* — к. разохотить.

**РАЗОХО'ЧИВАТЬСЯ** *несов. разг. редко* — к. разохотиться.

**РАЗОЧАРОВА'НИЕ** *ср.* — 1. күңел кайту, күңел бизү, күңел суыну; 2. өметсезлек, ышаныч бетү; *глубокое разочарование* — тирән өметсезлек.

**РАЗОЧАРО'ВАННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. к. разочарование; 2. төшенкелек, дөньядан туйганлык, пессимизм.

**РАЗОЧАРО'ВАННЫЙ** — күңеле бизгән, күңеле кайткан, күңеле суынган; өмете өзелгән, тормыштан туйган; өметсезлеккә төшкән.

**РАЗОЧАРОВА'ТЬ** *сов.* — күңелен биздерү, күңелен кайтару, күңелен суыту; ышанычын югалту; *он разочаровал всех своим выступлением* — ул үзенең чыгышы белән барысының да күңелен кайтарды (барысы да канәгатьсез булып калдылар).

**РАЗОЧАРОВА'ТЬСЯ** *сов.* — күңел кайту, күңел суыну, күңел бизү; күңел сүрелү; өмет өзелү (юкка чыгу), ышаныч бетү.

**РАЗОЧАРО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. разочаровать.

**РАЗОЧАРО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. разочароваться; 2. *страд.* күңеле биздерелү, күңеле суытылу.

**РАЗРАБА'ТЫВАТЬ** *несов.* — к. разработать.

**РАЗРАБА'ТЫВАТЬСЯ** *несов. устар.* — 1. к. разработаться; 2. *страд.* эшкәртелү, эшләп чыгарылу.

**РАЗРАБО'ТАННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. тузганлык, ашалганлык; *разработанность оси* — күчәрнең ашалганлыгы; 2. *науч.* эшләнгәнлек, эшкәртелгәнлек; тирәнтен өйрәнелгәнлек, тикшерелгәнлек; 3. *горн.* (файдалы казылманың) казып алынып беткән булуы; чыгарылып, (эшкәртелеп) беткән булуы; 4. эшләнеш, эшләнү сыйфаты; *слабая разработанность темы* — теманың эшләнеше йомшак булу.

**РАЗРАБО'ТАННЫЙ** — 1. *спец.* тузган; ашалып (кырылып, шомарып) беткән; *разработанная втулка* — тузган втулка; 2. *страд.* эшкәртелгән, эшләнгән; эшкәртелеп (хәзерләнеп) куелган; 3. яхшыртылган, үстерелгән, камилләштерелгән, эшләнгән (мәсәлән, тавыш, уен техникасы); 4. һәрьяклап өйрәнелгән, тикшерелгән (мәсьәлә); төзелгән (проект); 5. эшкәртелеп беткән, казып алып бетерелгән, чыгарып бетерелгән (мәсәлән, рудник).

**РАЗРАБО'ТАТЬ** *сов.* — 1. эшкәртү (эшләү, ясау); *разработать гранит на плиты* — гранит ташны плиталар итеп эшкәртү; 2. *с.-х.* эшкәртү, сөрү, йомшарту; *разработать почву под кукурузу* — туфракны (җирне) кукуруз игү өчен эшкәртү; 3. *горн.* (берәр казылма) чыгару өчен хәзерләп, (эшкәртеп) кую; *разработать рудник* — рудникны руда чыгару өчен хәзерләп кую; 4. *перен. спец.* эшкәртеп яхшырту; эшкәртеп камилләштерү, үстерү (мәсәлән, җырчының тавышын, музыкантның уен техникасын); 5. *перен. науч.* җентекләп эшләү, тирәнтен тикшерү, тирәнтен өйрәнү; *разработать вопрос* — мәсьәләне тирәнтен тикшерү; 6. төзү; *разработать проект* — проект төзү; 7. *горн.* чыгарып бетерү, (казып) алып бетерү.

**РАЗРАБО'ТАТЬСЯ** *сов. спец.* — эштән чыгу, тузу; шомарып бетү, кырылып бетү, ашалып бетү (мәсәлән, гайка, винт һ. б. ш.).

**РАЗРАБО'ТКА** *ж.* — 1. *только ед.* к.

разработать 1, 2, 3, 4, 5, 6; 2. *(степень разработанности)* эшләнеш, эшкәртелеш, эшләнү сыйфаты, эшкәртелү дәрәҗәсе; өйрәнелү дәрәҗәсе, тикшерелеш; 3. *только ед. спец.* чыгару, казу, алу (руда, күмер, торф һ. б. ш. кебек табигый байлыкларны эшкәртү эшләре); 4. *горн.* (казылма байлыкны) чыгару урыны.

**РАЗРА'ВНИВАТЬ** *несов.*— к. разровнить.

**РАЗРА'ВНИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— тигезләнү, тигезләп чыгылу (куелу); шомартылу, такырайтылу.

**РАЗРАЖА'ТЬСЯ** *несов. книж.*— к. разразиться.

**РАЗРАЗИ'ТЬ** *сов. книж. устар.* и *простореч.*: **разрази меня гром** — яшен суксын мине (ант иткәндә әйтелә).

**РАЗРАЗИ'ТЬСЯ** *сов.*— (гөрелдәп-шаулап) ява башлау; (дәһшәтле булып) башланып китү; *разразилась гроза* — (гөрелдәп-шаулап) яшенле яңгыр ява башлады; *разразилась война* — сугыш башланып китте. ◇ **Разразиться проклятиями** — ләгънәтләр яудыра (ләгънәт укый) башлау, бик нык каһәрләргә тотыну. **Разразиться громким смехом** — кычкырып (хахылдап, шаркылдап) көлеп җибәрү. **Разразиться громовой критикой** *(статьей)* — бик каты тәнкыйть (мәкаләсе) белән чыгу.

**РАЗРА'ЗНИВАТЬ** *несов. простореч.*— к. разрознивать.

**РАЗРА'ЗНИВАТЬСЯ** *несов. простореч.*— к. разрозниваться.

**РАЗРАСТА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— к. разрастаться.

**РАЗРАСТА'ТЬСЯ** *несов.*— к. разрастись.

**РАЗРАСТИ'СЬ** *сов.*— 1. үсеп зураеп китү, зур булып үсеп китү, күбәеп китү, ишәеп китү, куерып китү; *лес разросся* — урман зур булып үсеп киткән; 2. *перен.* зурга китү; *дело разрослось* — эш зурга китте.

**РАЗРАСТИ'ТЬ** *сов. книж.*— үстерү, күпләп үстерү.

**РАЗРАЩА'ТЬ** *несов. книж. редко* — к. разрастить.

**РАЗРАЩЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— к. разрастить, разрастись.

**РАЗРЕВЕ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. үкерә башлау; *вол разревелся* — үгез үкерә башлады; 2. *разг. фам.* үкереп елый башлау, кычкырып елап җибәрү, бертуктаусыз үкерү; *(о многих)* акырып елаша башлау; *ребёнок разревелся* — бала кычкырып елап җибәрде.

**РАЗРЕДИ'ТЬ** *сов.*— 1. сирәкләү, сирәгәйтү; сирәкләп утырту (мәсәлән, үрентеләрне); 2. *спец.* сирәкләндерү, сирәкләтү; *разредить воздух* — һаваны сирәкләтү.

**РАЗРЕДИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. сирәгәю, сирәкләшү; (аралары) киңәю, зураю; 2. сирәкләнү; *туман разредился* — томан сирәкләнде (сыекланды).

**РАЗРЕЖА'ТЬ** *несов.*— к. разредить.

**РАЗРЕЖА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. разредиться; 2. *страд.* сирәгәйтелү, сирәкләндерелү, сирәкләтелү.

**РАЗРЕЖЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. к. разредить, разредиться; 2. сирәклек; сирәкләнеш, сирәкләндереш.

**РАЗРЕЖЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *физ.*— сирәкләнгәнлек, сирәклек.

**РАЗРЕЖЁННЫЙ**: **разрежённый воздух** — сирәкләнгән һава; **разрежённый газ** — сирәкләтелгән газ.

**РАЗРЕ'З** *м.*— 1. *только ед. спец.* *(действие)* к. разрезать 1, 2; 2. киселеш, уелыш; *разрез воротничка* — яканың киселеше (уелышы); 3. *(разрезанное место)* киселгән урын, уем; 4. *науч. тех.* кисем, киселеш; *поперечный разрез* — аркылы кисем; *продольный разрез* — буйга киселеш (буйга киселгәндәге күренеше); 5. *мат.* киселмә; 6. *горн.* разрез (руда яки күмер чыгара торган урын). ◇ **В разрезе** *книж.*—... күзлегеннән чыгып;... яктан караганда; *судить о чем-н. в разрезе новых данных* — берәр нәрсә турында яңа мәгълүматлар күзлегеннән чыгып хөкем йөртү. **Разрез глаз** — күз уемы, күз уелышы. **Глубокий разрез на лбу от удара саблей** — маңгаенда кылыч белән чапканнан калган тирән эз (җөй).

**РАЗРЕЗА'ЛЬНЫЙ** *спец.*— кискеч, кисү...-ы; кисә (тураклый) торган; *разрезальная машина* — кисә торган машина (мәсәлән, кәгазь кискеч машина).

**РАЗРЕЗА'ЛЬЩИК** *м. спец.*— кисүче (эшче).

**РАЗРЕ'ЗАТЬ** *сов.*— 1. кисү, телү, турау, кискәләү; кисеп (телгәләп, тураклап) бетерү; кисеп кую; *разрезать арбуз* — карбыз кисү (телемләп); *разрезать ножницами сукно* — сукноны кайчы белән кискәләү; 2. яру, ярып җибәрү, ярып ачу; *разрезать живот* — эчен яру; 3. *спец.* кисү, (кисеп) бүлү; кисеп (бүлеп) бирү; *разрезать землю* — җир кисеп бирү; җир бүлеп бирү; 4. *воен.* кисеп үтү, ерып үтү; *разрезать неприятельский отряд* — дошман отрядын ерып үтү.

**РАЗРЕЗА'ТЬ** *несов.* — к. разре́зать.

**РАЗРЕ'ЗАТЬСЯ** *сов.*— киселү, туралу, ярылу.

**РАЗРЕЗА'ТЬСЯ** *несов.*— к. разре́заться.

**РАЗРЕЗНО'Й** *спец.*— 1. кисү...-ы; кисә (турый) торган; 2. *порт.* ерык; *разрезная юбка* — ерык итәкле юбка.

**РАЗРЕ'ЗЫВАТЬ** *несов.*— к. разре́зать.

**РАЗРЕ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. разрезаться.

**РАЗРЕКЛАМИ'РОВАТЬ** *сов. разг. неодобр. ирон.*— 1. күп игълан бирү, бик күп рекламалар белән белдерү; 2. *перен.* күкләргә күтәреп мактау, чиктән тыш мактау, артык рекламалап җибәрү.

**РАЗРЕША'ТЬ** *несов.*— к. разрешить.

**РАЗРЕША'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. разрешиться; 2. *безл.* рөхсәт ителү, ярау; *здесь курить не разрешается* — биредә тартырга рөхсәт ителми (ярамый).

**РАЗРЕШЕ'НИЕ** *ср.*— 1. *только ед.* к. разрешить, разрешиться; 2. рөхсәт; *разрешение на охоту* — ау аулау өчен рөхсәт; 3. *канц.* рөхсәт язуы, рөхсәт кәгазе; *покажите мне разрешение* — миңа рөхсәт язуыгызны күрсәтегез; 4. хәл ителеш, чишелеш, җавап; *верное разрешение проблемы* — проблеманың дөрес хәл ителеше; *найти*

*разрешение данной задачи* — бирелгән мәсьәләнең чишелешен табу, җавабын табу; 5. арыну, бушану, котылу; *разрешение от бремени* — йөктән котылу (бала тудыру). ◇ **С вашего разрешения** — сезнең рөхсәтегез белән, сез каршы килмәсәгез.

**РАЗРЕШЁННЫЙ** — 1. рөхсәт ителгән, рөхсәтле; 2. чишелгән, хәл ителгән, ачык; *разрешённый вопрос* — ачык мәсьәлә.

**РАЗРЕШИ'МЫЙ** *книж.* — хәл итәрлек, чишелерлек, чишелә торган; хәл итәргә мөмкин булган, хәл итеп була торган; *легко разрешимый вопрос* — җиңел хәл ителә торган мәсьәлә; *легко разрешимые геометрические задачи* — җиңел чишелә торган геометрик мәсьәләләр.

**РАЗРЕШИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж., спец.* — рөхсәт итү...-ы, рөхсәт...-ы; *разрешительный документ* — рөхсәт документы.

**РАЗРЕШИ'ТЬ** *сов.* — 1. рөхсәт итү, рөхсәт бирү; ирек бирү, ирек кую, юл кую; хокук (мөмкинлек) бирү; *разрешить гулять на улице* — урамда йөрергә рөхсәт итү; *разрешить книгу к печати* — китапны бастырып чыгарырга рөхсәт бирү; 2. *книж.* чишү, хәл итү, хәл кылу; *разрешить трудный научный вопрос* — авыр фәнни мәсьәләне хәл кылу; *разрешить спор* — бәхәсне хәл итү; 3. *школьн.* чишү, чыгару; *ты разрешил задачу по алгебре?* — син алгебрадан бирелгән мәсьәләне чиштеңме? 4. *церк. устар.* кичерү, ярлыкау, бушату; *разрешить от грехов* — гөнаһларын кичерү, ярлыкау; 5. *устар.* дәвалап төзәтү; *разрешить зрение* — дәвалап күзне төзәтү (күрә башлау). ◇ **Разрешить сомнения** — шик-шөбһәләрне бетерү, юкка чыгару. **Разрешить молчание** — тынлыкны бозу (сөйләшмичә, тып-тын торганда сөйли башлау).

**РАЗРЕШИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. хәл ителү, хәл кылыну, чишелү, ачыклану; табылу; *вопрос разрешился* — мәсьәлә хәл ителде; 2. бетү, тәмам булу, төгәлләнү, нәтиҗәгә килену; *дело разрешилось* — эш тәмам булды; 3. *книж. устар.* котылу, бала табу, тудыру; *благополучно разрешилась от бремени* — исән-сау баладан котылды (бала тапты); 4. *перен. разг. ирон.* көч-хәл белән әйтү; *разрешился плоской остротой* — көч-хәл белән генә тапкыр сүз әйткән булды (кемне дә шаккатыра алмады). ◇ **Разрешиться слезами** — ахырда елап җибәрү. **Разрешиться выкидышем** — (*о людях*) бала төшерү; (*о животных*) тума салу. **Болезнь разрешилась кризисом** — авыру кризис белән бетте.

**РАЗРИСО'ВАННЫЙ** — бизәкле, рәсемле, бизәкләп (рәсемләп) бетерелгән.

**РАЗРИСОВА'ТЬ** *сов.* — 1. рәсем ясау, бизәү, бизәкләп бетерү; бизәп чыгу; рәсем төшереп чыгу; бизәкләп-сырлап бетерү; *мальчик разрисовал обложку тетради* — малай дәфтәр тышын бизәкләп бетергән; 2. *перен. разг.* артык мактау яки артык яманлау; яхшы яки яман якларын тасвирләп сөйләп бирү.

**РАЗРИСО'ВКА** *ж. мн.* нет — к. разрисовать.

**РАЗРИСО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. разрисовать.

**РАЗРИСО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — бизәкләп чыгылу, артык бизәкләп бетерелү, рәсемнәр белән бизәкләнү.

**РАЗРОВНЯ'ТЬ** *сов.* — тигезләү, тигезләп чыгу, такырайту.

**РАЗРОДИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *обл.* (*расплодиться, разрастись*) үрчү, күбәю, ишәю; үрчеп китү; ишәеп китү; котырып үсү; бик уңу; 2. *простореч.* баладан котылу, тудыру, бала табу; *роженица с трудом разродилась* — бала тудыручы хатын баладан бик авыр котылды (баласын бик авыр тапты).

**РАЗРО'ЗНЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — (ише-ишеннән) аерылганлык, таркаулык; таркалганлык; комплекты тулы булмау.

**РАЗРО'ЗНЕННО** *нареч.* — таркау рәвештә, аерым-аерым рәвештә; *разрозненно действовать* — таркау рәвештә хәрәкәт итү (эш итү).

**РАЗРО'ЗНЕННЫЙ** — 1. ише аерылган, сыңарлы-сыңарсыз, ишсез, парсыз; *разрозненные перчатки* — сыңарлы-сыңарсыз перчаткалар; 2. ким, тулы (бөтен) булмаган; *разрозненный комплект* — тулы булмаган комплект; 3. аерым-аерым, таркау, бердәм булмаган; *разрозненные выступления* — аерым-аерым чыгышлар; *прежние разрозненные крестьянские хозяйства* — элеккеге таркау крестьян хуҗалыклары.

**РАЗРО'ЗНИВАТЬ** *несов.* — к. разрознить.

**РАЗРО'ЗНИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. разрозниться; 2. *страд.* ишеннән аерылу, комплекты бозылу, ишләре буталу.

**РАЗРО'ЗНИТЬ** *сов.* — 1. ишләрен саташтыру, парларын буташтыру; ишсез итү, сыңарын югалту; *разрознить сапоги* — итекнең ишләрен бутау (ишен алмаштыру); 2. комплектын бозу, тулылыгын бозу; таркату, бутап бетерү.

**РАЗРО'ЗНИТЬСЯ** *сов.* — комплекты бозылу, комплекты тулы булмау; ише (сыңары) югалу, буталу; *сервиз разрознился* — сервизның комплекты бозылган.

**РАЗРОНЯ'ТЬ** *сов. разг.* — коеп бетерү, төшереп бетерү; *разронять все деньги* — бөтен акчаны коеп бетерү.

**РАЗРУ'Б** *м.* — (балта белән) чабылган урын, киселгән урын; *дерево в разрубе сгнило* — агачның чабылган урыны черегән.

**РАЗРУБА'ТЬ** *несов.* — к. разрубить.

**РАЗРУБА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — (балта белән) чабылу, киселү.

**РАЗРУБИ'ТЬ** *сов.* — (балта һ. б. белән) чабу, чабып чыгару, кисеп чыгару, чабып өзү; (чабып) тураклау, ваклау; *разрубить дерево* — агачны кисеп чыгару; *разрубить мясо топором* — итне балта белән чабып ваклау.

**РАЗРУГА'ТЬ** *сов. разг. фам.* — к. разбранить.

**РАЗРУГА'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.* — к. разбраниться.

**РАЗРУ'ГИВАТЬ** *несов. разг. фам.* — к. разругать.

**РАЗРУ'ГИВАТЬСЯ** *несов. разг. фам.* — к. разругаться.

**РАЗРУМЯ'НИВАТЬ** *несов.* — к. разрумянить.

**РАЗРУМЯ'НИВАТЬСЯ** *несов.* — к. разрумяниться.

**РАЗРУМЯ'НИТЬ** *сов.* — 1. *разг.* (биткә) иннек сөртү, кызыл ягу; 2. *перен.* кызарту, алсуландыру; кызартып (алсуландырып) җибәрү; *мороз разрумянил щеки детей* — суык балаларның яңакларын кызарткан.

**РАЗРУМЯ'НИТЬСЯ** *сов.* — 1. *разг.* иннек сөртенү, иннек ягыну; 2. кызару, алсулану, кызарып (алсуланып) китү, кызыллык йөгерү; *от волнения лицо девочки разрумянилось* — дулкынланудан кызчыкның йөзенә кызыллык йөгерде.

**РАЗРУ'ХА** *ж. мн.* нет — 1. *старин. (раздор, смута)* үзара тынышмау, низаг; 2. таркалу, таркалыш; җимереклек, бөлгенлек; *империалистическая война привела хозяйство многих капиталистических стран к разрухе* — империалистик сугыш күп капиталистик илләрнең хуҗалыгын таркалуга китерде (бөлгенлеккә төшерде).

**РАЗРУША'ТЬ** *несов.* — к. разрушить.

**РАЗРУША'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. разрушиться; 2. *страд.* харап ителү, вәйран ителү, җимерекләргә әйләндерелү.

**РАЗРУШЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед.* к. разрушить, разрушиться; 2. җимереклек, хәрабә.

**РАЗРУ'ШЕННЫЙ** — җимерек; җимерелгән, ватылган, ишелгән; вәйран (булган), харап ителгән.

**РАЗРУШИ'ТЕЛЬ** *м. книж.* — җимерүче, бозучы, таркатучы; *разрушитель семейного счастья* — семья бәхетен җимерүче (таркатучы).

**РАЗРУШИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — җимерү (вату) көче; җимергеч булу, зыянлылык, зарарлылык.

**РАЗРУШИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — 1. җимерү...-ы, вату...-ы, җимергеч, җимерә торган; *разрушительное действие динамита* — динамитның җимерү тәэсире (вату көче); 2. *перен.* зарарлы, зыянлы, җимергеч; *разрушительное действие алкоголя на организм* — алкогольнең организмга зарарлы тәэсире.

**РАЗРУ'ШИТЬ** *сов.* — 1. җимерү, вату, ишү; ишеп, актарып ташлау; ватып, аударып бетерү; *разрушить стену* — стенаны җимерү; *разрушить мост* — күперне вату; 2. җимерекләргә (хәрабәләргә) әйләндерү, җимерү, вәйран итү; пыран-заран китерү; *землетрясение разрушило половину города* — җир тетрәү шәһәрнең яртысын җимерде; 3. ватып ташлау, җимерү, юк итү; тар-мар итү, таркату; *разрушить до основания* — нигезенә кадәр таркату; 4. бөлдерү, бөлгенлеккә төшерү; *разрушить экономику* — экономиканы бөлгенлеккә төшерү; 5. *перен.* какшату, эштән чыгару, зарар китерү; *разрушить здоровье* — сәламәтлекне какшату (саулыгын бетерү); 6. *перен.* юкка чыгару, җимерү; *разрушить надежды* — өметләрне юкка чыгару.

**РАЗРУ'ШИТЬСЯ** *сов.* — 1. җимерелү, ватылу, ишелү, ишелеп төшү; җимерелеп бетү, вәйран булу, җимерекләргә әйләнү; *забор разрушился* — койма җимерелгән; 2. таркалу, җимерелү, бөлү, бөлгенлеккә төшү; *хозяйство разрушилось* — хуҗалык таркалды; 3. *перен. (о здоровье)* бетү, какшау, эштән чыгу; 4. *перен.* юкка чыгу, җилгә очу; *все надежды разрушились* — барлык өметләр юкка чыкты.

**РАЗРЫ'В** *м.* — 1. *только ед.* к. разорвать 5; 2. *только ед.* к. разорваться; *разрыв сухожилий* — сеңерләрнең өзелүе; *разрыв снаряда* — снарядның шартлавы (ярылуы); 3. *тех. мат.* өзелү, өзелеш; *испытание материалов на разрыв* — материалларның өзелүгә чыдамлыгын сынау; *разрыв функции (мат.)* — функция өзелеше; 4. өзек, өзелгән урын; *найти разрыв кабеля* — телефон чыбыгының өзелгән урынын табу; 5. ачык ара, ачыклык; *разрывы между тучами* — болытлар арасындагы ачыклыклар; 6. *перен.* аерма; *разрыв между приходом и расходом* — керем белән чыгым арасындагы аерма; 7. аерылу, аерылганлык; бәйләнешсезлек; *разрыв между словом и делом* — сүзнең эштән аерылуы, аерылганлыгы; 8. ара өзелү, бозылу; *между ними произошёл разрыв* — аларның арасы өзелде, аларның арасы бозылды. ◇ **Разрыв-трава** — 1. *бот.* зәһәр ут (бер төркем агулы үсемлекләр); 2. *нар.-поэт.* тылсымлы үлән (рус әкиятләрендә бикләрне, йозакларны ватып ача торган үлән).

**РАЗРЫВА'ТЬ** I *несов.* — к. разорвать.

**РАЗРЫВА'ТЬ** II *несов.* — к. разрыть.

**РАЗРЫВА'ТЬСЯ** I *несов.* — 1. к. разорваться; 2. *страд.* ерткалап ташлану, ертып бетерелү; шартлатылу; ара (бәйләнеш) өзелү. ◇ **Душа (сердце) разрывается** — күңел әрни, йөрәк телгәләнә, йөрәк өзгәләнә (жәлләүдән ачыну турында).

**РАЗРЫВА'ТЬСЯ** II *несов. страд.* — казылу, казылып ташлану, казып алыну; актарылу, актарып ташлану.

**РАЗРЫВНО'Й** — 1. *воен.* ярылучан, ярыла торган; *разрывная пуля* — ярыла торган пуля; 2. *мат.* өзелешле; *разрывная функция* — өзелешле функция. ◇ **Разрывная длина** *тех.* — өзелүгә чыдау озынлыгы.

**РАЗРЫДА'ТЬСЯ** *сов.* — үкереп елап җибәрү, акырып елый башлау; үксеп-үксеп елый башлау.

**РАЗРЫ'ТЬ** *сов.* — 1. казып ташлау, актарып ташлау, казып (ачып) алу, казып (актарып) бетерү; *разрыть могилу* — каберне актарып ташлау; 2. *перен. разг. фам.* актарып ташлау; таратып (туздырып) ташлау; *он разрыл все мои бумаги* — ул минем бөтен кәгазьләремне таратып (туздырып) ташлаган (кәгазьләремдә казынган, актарынган).

**РАЗРЫХЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *спец.* — к. разрыхлить, разрыхлиться.

**РАЗРЫХЛЕ'ТЬ** *сов.* — йомшарып китү, көпшәкләнеп китү, кабарып китү, күпереп китү (җир).

**РАЗРЫХЛИ'ТЕЛЬ** *м. спец.*: **культиватор-разрыхлитель** *с.-х.* — йомшарткыч-культиватор.

**РАЗРЫХЛИ'ТЕЛЬНЫЙ** *спец.* — йомшарту...-ы, йомшарта торган, йомшарткыч...;

*разрыхлительное приспособление* — йомшарткыч җайланма.

**РАЗРЫХЛИ'ТЬ** *сов. спец.* — йомшарту; *разрыхлить землю* — җирне йомшарту.

**РАЗРЫХЛИ'ТЬСЯ** *сов. спец.* — көпшәкләнү, йомшару; күпереп китү.

**РАЗРЫХЛЯ'ТЬ** *несов. спец.* — к. разрыхлить.

**РАЗРЫХЛЯ'ТЬСЯ** *несов. спец.* — 1. к. разрыхлиться; 2. *страд.* йомшартылу, йомшартып күпертелү.

**РАЗРЯ'Д** I *м.* — 1. бүлек, төркем; катлау; *разряд растений* — үсемлекләр төркеме; 2. дәрәҗә, төр, сорт, разряд; *высший разряд* — югары дәрәҗә; *слесарь пятого разряда* — бишенче разрядлы слесарь; 3. *мат.* цифрның урыны; 4. *истор.* к. разрядный приказ.

**РАЗРЯ'Д** II *м.* — к. разрядить II 1, 2, 3; разрядиться II 1, 2; *разряд ружья* — мылтыкны бушандыру (ату яки патронын чыгару); *электрический разряд* — электрик бушану; *грозовой разряд* — яшен бушануы.

**РАЗРЯДИ'ТЬ** I *сов. разг. фам.* — бик шәп киендерү; купшы киендерү, киендерү-ясандыру.

**РАЗРЯДИ'ТЬ** II *сов.* — 1. патронын (снарядын) алу, корган зарядын алу; *разрядить орудие* — тупның снарядын кире алу; 2. атып бушандыру; *разрядить ружьё в мишень* — мылтыкны мишеньгә атып бушандыру; 3. *физ.* бушандыру; *разрядить батарею* — батареяны бушандыру; 4. *перен. книж.* (киеренкелекне) йомшарту (бетерү, киметү), җиңеләйтеп җибәрү; *его заявление разрядило атмосферу* — аның белдерүе киеренкелекне йомшартты.

**РАЗРЯДИ'ТЬСЯ** I *сов. разг. фам.* — бик купшы киенү; шәп киенү, киенү-ясану. ◇ Разрядиться в пух и прах — бик фырт киенү.

**РАЗРЯДИ'ТЬСЯ** II *сов.* — 1. (*об оружии*) атылып бушану, заряды алыну, патроны (снаряды) алыну, чыгарылу; 2. *физ.* бушану, тогы бетү, корылмасы бетү; *батарея разрядилась* — батареяның корылмасы беткән; 3. *перен. книж.* киеренкелек бетү (җиңеләю), куркыныч киму (мөнәсәбәтләрдә); *атмосфера разрядилась* — атмосфера җиңеләйде (киеренкелек бетте, куркыныч кимеде).

**РАЗРЯ'ДКА** *ж.* — 1. *тип.* разрядка, сирәкләтеп җыю (хәрефләрнең араларын киң калдырып җыю); *набрать слово разрядкой* — сүзне разрядка белән җыю; 2. *полит.* киеренкелек бетү (мөнәсәбәтләрдә); 3. к. разрядить II 1, 2.

**РАЗРЯ'ДНИК** I *м. физ. тех.* — бушандыргыч (электр приборларын автомат рәвештә бушандыра торган җайланма).

**РАЗРЯ'ДНИК** II *м. спорт.* — разрядлы спортчы.

**РАЗРЯ'ДНЫЙ** I: **разрядный приказ** *истор.* — разрядный приказ (Петрга кадәрге Россиядә хезмәт урыннарын һәм вазифаларны бүлеп бирү белән шөгыльләнүче учреждение).

**РАЗРЯ'ДНЫЙ** II *физ. мат.* — бушану ...-ы; разряд...-ы; *разрядный ток* — бушану тогы (электр корылмасы бушанган вакытта хасил була торган ток); *разрядное число* (*мат.*) — разряд саны.

**РАЗРЯЖА'ТЬ** I *несов. разг. фам.* — к. разрядить I.

**РАЗРЯЖА'ТЬ** II *несов.* — к. разрядить II.

**РАЗРЯЖА'ТЬСЯ** I *несов. разг. фам.* — 1. к. разрядиться I; 2. *страд.* купшы киендерелү, шәп киендерелү, киендерелү-ясандырылу.

**РАЗРЯЖА'ТЬСЯ** II *несов.* — 1. к. разрядиться II; 2. *страд.* (атып) бушандырылу; патроны (снаряды) алыну.

**РАЗРЯ'ЖЕННЫЙ** *разг. фам.* — купшы киемле, киенгән-ясанган.

**РАЗРЯЖЁННЫЙ** — бушандырылган; патроны (снаряды) алынган.

**РАЗРЯ'ЖИВАТЬ** *несов. разг. фам.* — к. разрядить I.

**РАЗРЯ'ЖИВАТЬСЯ** *несов. разг. фам.* — 1. к. разрядиться I; 2. *страд.* купшы итеп киендерелү.

**РАЗУБЕДИ'ТЬ** *сов.* — фикереннән кайтару; ниятен үзгәрттерү.

**РАЗУБЕДИ'ТЬСЯ** *сов.* — үз фикереннән кайту, карашы (фикере) үзгәрү, тоткан юлын ташлау.

**РАЗУБЕЖДА'ТЬ** *несов.* — к. разубедить.

**РАЗУБЕЖДА'ТЬСЯ** *несов.* — к. разубедиться.

**РАЗУБИРА'ТЬ** *несов. разг.* — к. разубрать.

**РАЗУБИРА'ТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. разубраться; 2. *страд.* җыештырылу, бизәлү.

**РАЗУБРА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. матур итеп җыештырып кую, бизәп кую; 2. (*нарядить*) матурлап киендерү, купшы итеп киендерү, киендерү-ясандыру.

**РАЗУБРА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — матур итеп киенү, бизәнү, киенү-ясану; *разубралась и гулять пошла* — матур итеп киенде дә йөрергә чыгып китте.

**РАЗУВА'ТЬ** *несов.* — к. разуть.

**РАЗУВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. разуться; 2. *страд.* аяк киеме салдырылу.

**РАЗУВЕРЕ'НИЕ** *ср. книж.* — 1. к. разуверить, разувериться; 2. *поэт.* (*разочарованность*) күңеле суыну, күңеле кайту, өметсезлек.

**РАЗУВЕ'РИТЬ** *сов. книж.* — ышанычын бетерү; уеннан кире кайтару, фикереннән дүндерү; *разуверить в друзьях* — дусларына ышанычын бетерү.

**РАЗУВЕ'РИТЬСЯ** *сов. книж.* — ышанычы бетү, күңеле кайту, уеннан кире кайту; *разувериться в друзьях* — дусларына ышанычы бетү.

**РАЗУВЕРЯ'ТЬ** *несов. книж.* — к. разуверить.

**РАЗУВЕРЯ'ТЬСЯ** *несов. книж.* — к. разувериться.

**РАЗУДА'ЛЫЙ** *нар.-поэт.* — бик кыю, бик батыр, гайрәтле; бик үткен (житез, чая); *разудалый добрый молодец* — гайрәтле батыр егет.

**РАЗУЗНАВА'ТЬ** *несов. разг.* — к. разузнать.

**РАЗУЗНАВА'ТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — беленү, тикшерелеп беленү, сорашып беленү.

**РАЗУЗНА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. яхшылап белү, белешү; җентекләп тикшереп белү, белеп бетерү, сораш (тыр) ып белү; *надо о нём разузнать как следует* — аның турында яхшылап белешергә кирәк; 2. белеп бетерү, белеп (сизеп) алу; *мало-помалу все разузнали* — әкренләп барысы да белеп бетергәннәр.

**РАЗУКРА'СИТЬ** *сов. разг.* — бизәү, бизәкләү, матурлау; бизәп бетерү; *разукрасить фасад дома флагами* — йортның урам ягын флаглар белән бизәү.

**РАЗУКРА'СИТЬСЯ** *сов. разг.* — матурлану, ямьләнү, бизәнү, бизәлү; купшылану, киенү-ясану.

**РАЗУКРАША'ТЬ** *несов. устар.* — к. разукрасить.

**РАЗУКРАША'ТЬСЯ** *несов. устар.* — к. разукраситься.

**РАЗУКРА'ШИВАТЬ** *несов. разг.* — к. разукрасить.

**РАЗУКРА'ШИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. разукраситься.

**РАЗУКРУПНЕ'НИЕ** *ср.* — к. разукрупнить, разукрупниться.

**РАЗУКРУПНИ'ТЬ** *сов.* — вак өлешләргә аеру, бүлү; бүлеп кечерәйтү.

**РАЗУКРУПНИ'ТЬСЯ** *сов.* — бүленеп кечерәю, вак бүлекләргә аерылу, бүленү.

**РАЗУКРУПНЯ'ТЬ** *несов.* — к. разукрупнить.

**РАЗУКРУПНЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. разукрупниться; 2. *страд.* кечерәйтелү; вак өлешләргә бүленү, аерылу.

**РА'ЗУМ** *м.*—1. *филос.* гакыл; *человек наделён разумом* — кешенең гакылы бар; 2. (*ум, сознание*) акыл, аң; *действовать с разумом* — акыл белән эш итү; 3. *книж. устар.* асыл мәгънә, төп төшенчә, төп эчтәлек, әһәмият; *разум слова* — сүзнең асыл мәгънәсе, төшенчәсе; *разум закона* — законның төп эчтәлеге (мәгънәсе, асылы). ◇ **Ум за разум заходит** (*у кого*) — баш катә, зиһен чуала. **Разум помутился** — исеннән-акылыннан язган. **Учить уму-разуму** — акыл бирү, акылга өйрәтү, үгетләү, үгетнәсихәт бирү.

**РАЗУМЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. *устар.* (*способность понимать*) аңлау сәләте, төшенү сәләте; 2. (*точка зрения*) уй, аңлау, фикер, караш; *по моему разумению, вы не правы* — минем аңлавымча, сез хаклы түгел.

**РАЗУМЕ'ЕТСЯ** *в знач. ввод. сл.* — билгеле, әлбәттә, мәгълүм ки, (үзеннән-үзе) аңлашыла ки; *разумеется, он придёт* — билгеле, ул киләчәк.

**РАЗУМЕ'ТЬ** *несов.* — 1. аңлау, төшенү; аңлап (төшенеп) алу; *разуметь смысл слова* — сүзнең мәгънәсенә төшенү (мәгънәсен аңлап алу); 2. *устар. простореч.* белү, суддыру; *разуметь по-французски* — французча белү (яки французчаны аңлау); *дело разуметь* — эшли белү, эшне булдыру; 3. *книж.* күздә тоту, аңлау, уйлау; *что вы разумеете под этим выражением?* — бу тәгъбирне сез ничек аңлыйсыз? ◇ **Дитя не плачет, мать не разумеет** — еламаган балага имчәк бирмиләр.

**РАЗУМЕ'ТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. (мәгънә) аңлашылу, (фикер) аңлашылу; уйланылу, күздә тотылу; 2. *страд. устар.* аңлатылу; *это выражение разумеется нами иначе* — бу тәгъбир безнең тарафтан икенче төрле аңлатыла.

**РАЗУ'МНИК** *м.*, **РАЗУ'МНИЦА** *ж.* — 1. акыллы, зирәк (бала); 2. *чаще ирон.* аңлы (төпле) кеше; акыл иясе, акыллы баш.

**РАЗУ'МНО** *нареч.* — акыллы итеп, акыл белән, аңлап; *разумно поступить* — акыл белән эш итү.

**РАЗУ'МНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — гакыллылык, акыллылык; акылга муафикълык; уйлап эш итү.

**РАЗУ'МНЫЙ** *книж.*—1. гакыллы, аңлы, гакылы булган; *человек существо разумное* — кеше гакыллы зат; 2. акыллы, зиһенле, фәһемле; төпле, төшенә торган, уйлап эш итә торган; *он юноша разумный* — ул бик акыллы егет; 3. акылга муафикъ, акылга сыешлы (туры килә торган); нигезле, логикалы; *разумный поступок* — акылга сыешлы (муафикъ) эш; *разумные доводы* — нигезле дәлилләр.

**РАЗУ'ТЫЙ** — (аяк киемен) салган, яланаяк.

**РАЗУ'ТЬ** *сов.* — аяк киемен салдыру; *разуть ребёнка* — баланың аяк киемен салдыру.

**РАЗУ'ТЬСЯ** *сов.* — аяк киемен салу, яланаяк калу.

**РАЗУТЮ'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. разутюжить.

**РАЗУТЮ'ЖИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг.* к. разутюжиться; 2. *страд.* үтүкләнелү, үтүкләп куелу, үтүкләп чыгылу.

**РАЗУТЮ'ЖИТЬ** *сов.* — 1. үтүкләү, үтүкләп кую; *разутюжить брюки* — чалбарны үтүкләп кую; 2. тигезләү, тигезләп чыгу (юлны махсус машина белән).

**РАЗУТЮ'ЖИТЬСЯ** *сов. разг.* — үтүкләнү; *брюки плохо разутюжились* — чалбар начар үтүкләнгән.

**РАЗУХА'БИСТОСТЬ** *ж. мн.* нет, *простореч.* — 1. егетлек, егетсыманлык; 2. әдәпсезлек, тупаслык.

**РАЗУХА'БИСТЫЙ** *простореч.* — 1. (*молодцеватый*) егет (сыман), үткен, булдыклы; 2. дәртле, җилле, гайрәтле, ялкынлы; *разухабистая пляска* — дәртле бию; 3. *неодобр.* чорсыз, тартынусыз, әдәпсез, тупас, тыйнаксыз; *разухабистые манеры* — тупас кыланышлар.

**РАЗУ'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. разучить.

**РАЗУ'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. разучиться; 2. *страд.* ятлану, яттан өйрәнелү, ятка (хәтергә) алыну, бикләнелү.

**РАЗУЧИ'ТЬ** *сов.* — 1. ятлау, (күңелгә) бикләү, (яттан) өйрәнү; *разучить песню* — җыр өйрәнү; *разучить свою роль* — үз ролеңне яттан өйрәнү; *разучить стихи* — шигырь ятлау; 2. *разг. ирон.* белгәнне оныттыру, хәтереннән чыгарту.

**РАЗУЧИ'ТЬСЯ** *сов.* — (өйрәнгәнне) оны-

тып бетерү, (белгәнне) оныту; белми башлау.

**РАЗЪЕДА'ТЬ** *несов.* — 1. *разг.* к. разъесть; 2. *перен. книж.* какшату, таркату, эчтән җимерү; *противоречия разъедают империализм* — каршылыклар империализмны какшаталар (эчтән җимерәләр).

**РАЗЪЕДА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *просторен.* к. разъесться; 2. *страд.* ашалу, киселү, уелу (мәс., кислотадан); 3. *страд. перен.* какшатылу, таркатылу; эчтән җимерелү.

**РАЗЪЕДИНЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — 1. к. разъединить; 2. аерылу; өзелү; аерылып (өзелеп) тору; *разъединение тока продолжалось два часа* — токның өзелеп торуы ике сәгать дәвам итте.

**РАЗЪЕДИНИ'ТЕЛЬ** *м. тех.* — аеручы, өзүче; аергыч, өзгеч, бүлгеч.

**РАЗЪЕДИНИ'ТЬ** *сов. книж.* — 1. аеру; *судьба их разъединила* — язмыш аларны аерды; 2. өзү, өзеп кую; *разъединить телефонные аппараты* — телефон аппаратларын өзү.

**РАЗЪЕДИНИ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — 1. аерылу, аерылышу, аерылы(шы)п китү; *сначала ехали вместе, потом разъединились* — башта бергә бардылар, ә соңыннан аерылышып киттеләр; 2. өзелү, элемтә (бәйләнеш) өзелү; *провода разъединились* — электр чыбыклары өзелде.

**РАЗЪЕДИНЯ'ТЬ** *несов. книж.* — к. разъединить.

**РАЗЪЕДИНЯ'ТЬСЯ** *несов. книж.* — к. разъединиться.

**РАЗЪЕ'ЗД** *м.* — 1. к. разъехаться 1; 2. *только ед.* юл сабышу; юл бирешү; *разъезд машин* — машиналарның юл бирешүләре (юл бирешеп үтеп китүләре); 3. к. разъезжать; *служебные разъезды* — хезмәт эшләре буенча юлда йөрү; 4. *воен.* разъезд, атлы күзәтчеләр яки атлы сакчылар (разведкага яки сакларга җибәрелгән кечкенә хәрби отряд); 5. *ж.-д.* разъезд (бер колеялы тимер юлда каршы килгән поездларны үткәреп җибәрә торган икенче юл); 6. *ж.-д.* разъезд (поезд туктала торган кечкенә станция). ◇ **Он целый день в разъезде** — ул көне буе әле анда, әле монда чаба (ат яки машинада).

**РАЗЪЕ'ЗДИТЬ** *сов.* — күп йөреп юлны бозу (эштән чыгару), чокыр-чакырлап (сикәлтәләп, салулатып) бетерү.

**РАЗЪЕ'ЗДИТЬСЯ** *сов. разг.* — күп йөри башлау, әрле-бирле (бертуктаусыз) йөри башлау; *автомобили разъездились по переулку* — тыкрыктан бертуктаусыз автомобильләр йөри башлады.

**РАЗЪЕЗДНО'Й**: **разъездной путь** *спец.* — каршы поездны үткәрү юлы (каршы килгән поездга юл бирү өчен, тимер юлның икегә аерылган урыны); **разъздные деньги** — юл акчасы, юлга бирелә торган акча; **разъездной агент** — урыннарда йөрүче агент; **разъездная труппа** *театр.* — күчмә труппа.

**РАЗЪЕЗЖА'ТЬ** *несов.* — 1. (атта һ. б. транспортта) йөрү, йөреп тору, юл йөрү, сәфәр йөрү; юлда йөрү, төрле урынnарга барып-килеп йөрү; *разъезжать по делам службы* — хезмәт эшләре белән юлда йөрү; 2. сәяхәт итү, ил гизү, гизеп йөрү; *разъезжать по всей стране* — бөтен илне гизеп йөрү.

**РАЗЪЕЗЖА'ТЬСЯ** *несов.* — к. разъехаться.

**РАЗЪЕ'ЗЖЕННЫЙ** — йөреп бозылган; сикәлтәле, казылмалы, салуланып беткән; *разъезженная дорога* — сикәлтәле юл.

**РАЗЪЕ'ЗЖИВАТЬ** *несов.* — к. разъездить.

**РАЗЪЕ'ЗЖИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг.* к. разъездиться; 2. *страд.* (күп йөрүдән) бозылу, ашалу; казылып (салуланып, чокыр-чакырланып) бетерелү.

**РАЗЪЁМ** *м. мн.* нет, *тех.* — к. разнять 1.

**РАЗЪЕ'СТЬ** *сов. разг.* — 1. *(о кислоте, о ржавчине)* ашау, кисү, ую; кисеп бетерү; *ржавчина разъела железо* — тимерне тутык ашаган; *щёлочь разъела руки* — кулымны селте уеп бетерде; 2. ачыттыру, әчеттерү; 3. *просторен.* ашап бетерү (җыйнаулашып, бергәләшеп); *с друзьями всё разъели, что было* — иптәшләр белән хәзинәдә булганның барысын ашап бетердек.

**РАЗЪЕ'СТЬСЯ** *сов. просторен.* — 1. ашауга бирелү, ашау белән мавыгып китү; 2. (күп ашаудан) тазару, симерү, юанаю; симереп китү; *ишь, разъелся как на готовых хлебах!* — кара син аны, әзерне ашап ничек симереп киткән!

**РАЗЪЕ'ХАТЬСЯ** *сов.* — 1. (төрле якка) таралу, таралышу, таралып бетү, китеп бетү (атта, машинада һ. б. да); *гости давно разъехались* — кунаклар күптән таралдылар; 2. аерылу, аерылышып китү, икесе ике якка китү; *мы с ним разъехались* — без аның белән аерылышып киттек; 3. *(о супругах)* аерылу, аерылышу; 4. юл сабышу, юл бир(еш)ү (очрашканда бәрелешмичә үтеп китү, узып китү); *дорога такая узкая, что трудно разъехаться* — юл шундый тар, (олаулар очрашканда) юл сабып үтәргә дә кыен; 5. *разг.* аймыл(ыш) булу; очрашмый үтеп китү (атта, машинала һ. б. да барганда); 6. *разг.* икесе ике якка шуып китү, таеп аерылып китү (аяклар яки чаңгылар); 7. *перен. просторен.* тузу, сыпылу; тетелеп бетү, тузып таралып бетү; *вся рубашка разъехалась* — күлмәк тетелеп беткән.

**РАЗЪЮЛИ'ТЬСЯ** *сов. разг. ирон.* — артык ялагайлана башлау, тәмле телләнү; тирәсендә бөтерелү (берәүгә ярарга тырышып), артык юмалана башлау.

**РАЗЪЯРЁННЫЙ** — ачулы, ярсу; котырынган, шашкан, ярсыган, ачуы кабарган, ачуы килгән, бик кызган; *разъярённый неудачей* — уңышсызлыктан ачуы кабарган.

**РАЗЪЯРИ'ТЬ** *сов.* — ачуландыру, ярсыту, ярсытып җибәрү, кыздыру; ачуын китерү, ачуын чыгару, ачуын кабарту, котырту; *неудача разъярила его* — уңышсызлыкка очравы аның ачуын китерде.

**РАЗЪЯРИ'ТЬСЯ** *сов.* — ярсу, ярсып китү, ачу кабару, ачу килү; котырыну; гайрәт чәчү.

**РАЗЪЯРЯ'ТЬ** *несов.* — к. разъярить.

**РАЗЪЯРЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. разъяриться; 2. *страд.* ярсытылу, ачуландырылу.

**РАЗЪЯСНЕ'НИЕ** *ср.*—1. *только ед.* к. разъяснить; *разъяснение дела* — эшне ачыклау; 2. *офиц.* аңлатма, ачыклау язуы; *официальное разъяснение* — рәсми аңлатма.

**РАЗЪЯ'СНИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. разъясниться.

**РАЗЪЯСНИ'ТЕЛЬНЫЙ** — аңлату...-ы; төшендерү...-ы; *разъяснительная работа* — аңлату эшләре.

**РАЗЪЯ'СНИТЬ** *сов. безл. простореч.* — көн ачылу, аязу; аязып (ачылып) китү; *к вечеру разъяснило* — кичкә көн аязып китте.

**РАЗЪЯСНИ'ТЬ** *сов.*—1. *книж.* төшендерү; аңлату, ачыклау, аңлатып бирү, төшендереп бирү; *разъяснить значение слова* — сүзнең мәгънәсен аңлатып бирү; 2. *перен. разг. ирон. устар.* (*разоблачить*) фаш итү, ачып салу.

**РАЗЪЯ'СНИТЬСЯ** *сов. разг.* — к. разъясниться.

**РАЗЪЯСНИ'ТЬСЯ** *сов.* — ачылу, ачыклану, аңлашылу.

**РАЗЪЯСНЯ'ТЬ** *несов.* — к. разъяснить.

**РАЗЪЯСНЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. разъясниться; 2. *страд.* аңлатылу, төшендерелү, ачыкланылу, аңлатып (ачыклап) бирелү.

**РАЗЪЯ'ТЬ** *сов. книж. ритор. устар.* — к. разнять.

**РАЗЪЯ'ТЬСЯ** *сов. книж. ритор. устар.* — к. разняться.

**РАЗЫГРА'ТЬ** *сов.* — 1. *театр.* уйнау, башкару, уйнап күрсәтү, уйнап чыгу, кую; *артисты разыграли новую пьесу* — артистлар яңа пьеса уйнадылар (куйдылар, күрсәттеләр); 2. өйрәнү, ятлау, ятлап чыгу (көйне, рольне); 3. *перен.* ...булып кылану; ...-га салышу, ...итеп күрсәтү; *разыграть простачка* — үзеңне беркатлы кеше итеп күрсәтү; 4. уйнау; уйнап чыгу, уенны төгәлләү; *с большим искусством разыграл эндшпиль* — эндшпильне зур осталык белән уйнап чыкты; 5. (карта уенында)... белән йөрү; ...белән чыгу; *разыграть пику* — пикилар белән йөрү; 6. (лотореяда) уйнату; (шобага салып) уйнату; *разыграть десять выигрышей* — ун отыш уйнату; 7. *простореч. фам.* шаярту, шаяртып көлү, шаяртып үртәү, мәзәк итү, шаяртып көлкегә калдыру; *разыграть приятеля* — иптәштән шаяртып көлү. ◇ **Разыграть дурака** *простореч.* — ахмаклык эшләү, ахмак булып калу. **Разыграть роль** — 1. роль башкару; 2. ... ролен башкару.

**РАЗЫГРА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. уен белән мавыгып китү, уенга бирелеп китү; *дети разыгрались* — балалар уенга бирелеп киттеләр; 2. *разг.* кызып уйный башлау, дәртләнеп уйный башлау; *пианист разыгрался* — пианист дәртләнеп уйный башлады; 3. көчәеп китү, котырыну, дулау; кузгалып (кабынып) китү; кызып китү, җәелеп китү; *буря разыгралась* — давыл көчәеп китте (котырынды).

**РАЗЫ'ГРЫВАТЬ** *несов.* — к. разыграть.

**РАЗЫ'ГРЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. разыграться; 2. *страд.* уйналу, башкарылу.

**РАЗЫМА'ТЬ** *несов. простореч.* и *книж. устар.* —к. разнять.

**РАЗЫМА'ТЬСЯ** *несов. простореч.* и *книж. устар.* —1. разниматься: 2. *страд.* аерылу, аерып алыну, аерып куелу; сүтелү.

**РАЗЫ'МЧИВЫЙ** *устар.* и *обл.* — бик тәэсирле, дәртләндерә (җилкендерә) торган, кузгата торган.

**РАЗЫСКА'НИЕ** *ср. книж.* — 1. *только ед. книж. устар.* эзләү, эзләп табу; 2. *только мн.* фәнни эзләнүләр, фәнни тикшеренүләр; фәнни әсәр.

**РАЗЫСКА'ТЬ** *сов.* — 1. табу, эзләп табу; *разыскать пропавшую вещь* — югалган әйберне эзләп табу; 2. *истор.* (*произвести следствие*) тикшерү, тикшереп белү, тикшереп табу.

**РАЗЫСКА'ТЬСЯ** *сов.* — табылу, эзләп табылу.

**РАЗЫ'СКИВАТЬ** *несов.* — 1. эзләү; 2. к. разыскать.

**РАЗЫ'СКИВАТЬСЯ** *несов.*—1. к. разыскаться; 2. *страд.* эзләнү; тикшерелеп беленү.

**РАЗЯ'ЩИЙ** — үткен, кискен; какшаткыч, җимергеч; *разящие удары по врагу* — дошманга җимергеч һөҗүмнәр ясау.

**РАИ'НА** *ж. обл.* — раина, көньяк тополе.

**РАЙ** *м. мн.* нет — 1. *религ.* җәннәт, оҗмах; 2. *перен.* оҗмах, бик шәп урын (бәхетле һәм рәхәт яши торган урын); *здесь прямо рай* — монда чын оҗмах. ◇ **Отправить в рай** *ирон. перен.* — теге дөньяга җибәрү. **Земной рай** или **рай земной** *книж. перен.* — бәхет иле, рәхәт тормыш, бәхет бакчасы.

**РА'ЙГРАС** *м. бот.* — райграс, айравык (күпьеллык мал азыгы үсемлеге).

**РАЙВОЕНКОМА'Т** (*районный военный комиссариат*) *м.* — райвоенкомат, район хәрби комиссариаты.

**РАЙИСПОЛКО'М** (*районный исполнительный комитет*) *м.* — райисполком, райбашкарма (район башкарма комитеты).

**РАЙКО'ВЫЙ** — раёк...-ы; *райковая публика* — раёк халкы, раёктагы тамашачылар (театрның иң өске ярусында утыручылар).

**РАЙКО'М** *м.* (*районный комитет*) — райком, район комитеты (мәсәлән, КПССның район комитеты).

**РАЙОН** *м.* — 1. (*административная единица*) район; *Челнинский район Татарии* — Татарстанның Чаллы районы; *Бауманский район Казани* — Казанның Бауман районы; 2. район; өлкә, урын; *степные районы* — далалы өлкәләр; *хлебные районы* — икмәк чәчә торган районнар (урыннар); 3. (*часть населённого пункта*) төбәк, тирә.

**РАЙОНИ'РОВАНИЕ** *ср. мн.* нет — к. районировать.

**РАЙОНИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — 1. *офиц.* районнарга бүлү, районнарга аеру; 2. *спец.* районлаштыру, җирләштерү, яраклаштыру (билгеле бер өлкә янсә районның табигый шартларына җайлаштыру).

**РАЙОНИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. офиц., спец.* — районнарга бүленү, районлаштырылу; (районнарга) яраклаштырылу.

**РАИО'ННЫЙ** *офиц.*— район...-ы; *районная конференция* — район конференциясе.

**РА'ЙСКИЙ — 1.** *религ.* җәннәт...-ы; оҗмах...-ы; оҗмахтагы; җәннәттәге; *райская птица*—оҗмах кошы; 2. *перен.* бәхетле, тыныч, иркен, мул; *райская жизнь* — бәхетле тормыш; 3. *перен. разг.* бик шәп, гаҗәп яхшы, соклангыч, бик ягымлы; *у неё райский голосок* — аның тавышы соклангыч (бик ягымлы).

**РАЙСОВЕ'Т** *(районный совет) м.* — райсовет, район советы (мәсәлән, хезмәт ияләре депутатларының район советы).

**РАЙЦЕ'НТР** *(районный центр) м.*— райүзәк, район үзәге.

**РАК** I *м. зоол.*—кысла; *красный, как рак*— пешкән кысладай кып-кызыл. ◇ **Показать, где раки зимуют** *разг. фам.*— к. зимовать. **Знать, где раки зимуют** *разг. фам.*— бик хәйләкәр булу, сизгер булу. **Когда рак свистнет** *разг. фам. ирон.*— кызыл кар яугач (беркайчан да булмаячак мәгънәсендә). **Как рак на мели** *разг.*— көймәләре комга терәлү (чарасыз калу). **Рак-отшельник** *зоол.*— поскын кысла. **Созвездие рака** *астр.*— саратан (күктәге бер йолдызлык).

**РАК** II *м. мн.* нет, *мед.*— рак, яман шеш (эчке һәм тышкы әгъзаларда була торган дәвамлы авыру); *рак желудка* — ашказаны рагы.

**РА'КА** *ж. церк.*— рака, табут (христиан чиркәвендә, янәсе изгеләрнең мәет калдыкларын саклана торган тимер әрҗә).

**РАКА'ЛИЯ** *ж. просторeч. бран.*— вөҗдансыз, оятсыз, кабахәт, әшәке.

**РА'КЕЛЬ** *м. спец. тип.*— ракель (типографиядә буяу кыру өчен кулланыла торган сыгылмалы пычак).

**РА'КЕЛЬНЫЙ** *тип.*— ракель..., тирән; *ракельная печать* — ракель басма, тирән басма.

**РАКЕ'ТА** I *ж.*— ракета (1. сигнал бирү өчен һәм фейерверкларда кулланыла торган махсус янар составлы снаряд; 2. реактив двигательдән чыккан газ басымы белән хәрәкәт итә торган очкыч аппарат).

**РАКЕ'ТА** II *ж. спорт.*— к. ракетка.

**РАКЕ'ТКА** *ж. спорт.*— ракетка, теннис калагы (теннис уенау өчен челтәрле калак).

**РАКЕ'ТНИЦА** *ж. спец.*— ракетница (ракета ата торган махсус пистолет).

**РАКЕ'ТНЫЙ** I *спец.*— 1. ракета...-ы; *ракетный сигнал* — ракета сигналы (ракета белән бирелгән сигнал); 2. *спец.* ракеталы, реактив; *ракетный двигатель* — реактив двигатель.

**РАКЕ'ТНЫЙ** II *спец. спорт.*— ракетка...-ы; теннис калагы...-ы; *ракетное производство* — ракетка производствосы (теннис калагы эшләп чыгару).

**РАКИ'ТА** *ж.*— өянке, тирәк, тал (тал агачының кайбер төрләре).

**РАКИ'ТНИК** *м.*— 1. *бот.* к. ракита; 2. тирәклек, тал куаклыгы.

**РАКИ'ТОВЫЙ** — тал...-ы; өянке...-ы; тирәк...-ы; *ракитовый куст* — тал куагы.

**РАКЛИ'СТ** *м. спец.*— раклист (туку эшендә бизәк төшерү машинасында эшләүче өлкән эшче).

**РА'КОВИНА** I *ж.*— 1. *биол.* кабырчык, бака кашыгы, бака кабыгы, моллюск кабырчыгы (йомшак тәнлеләрнең кабыгы); *раковина улитки* — әкәм-төкәм кабыгы; *жемчужная раковина* — энҗе кабырчыгы; 2. кабырчыктан ясалган әйберләр; 3. яфрак, кимерчәк; *ушная раковина* — колак яфрагы; *раковина носовая* — борын кимерчәге; 4. *горн.* таш эчендәге йомшак токым; 5. *спец.* бушлык, куышлык (коелган металл яки әзер эшләнмә эчендә куыш калган урыннар).

**РА'КОВИНА** II *ж.*— раковина (1. су краны астына куела торган чүлмәк савыт; 2. бәдрәфтәге чүлмәк савыт).

**РА'КОВЫЙ** I — кысла...-ы; *раковый суп* — кысла шулпасы.

**РА'КОВЫЙ** II *мед.*— рак...-ы; рак белән чирли торган; *раковая опухоль* — рак шеше (яман шеш); *раковый больной* — рак белән чирли торган авыру.

**РАКООБРА'ЗНЫЕ** *мн. зоол.* — кысласыманнар.

**РАКУ'РС** *м. живоп.*— ракурс (сурәтләнә торган әйберне перспективада биргәндә арткы пландагы өлешләрнең бик нык кечерәйтелгән булуы); *изобразить в ракурсе* — ракурс белән төшерү.

**РАКУ'ШЕЧНЫЙ** *геол.*— кабырчыклы, кабырчык...-ы; *ракушечный слой* — кабырчык катламы.

**РАКУ'ШКА** *ж.* — к. раковина I 1, 2.

**РА'ЛО** *ср. книж. устар.*— 1. сабан, сука; 2. *обл.* тәрән.

**РА'МА** *ж.*— 1. рам, кыса; *оконная рама* — тәрәзә рамы; *дверная рама* — ишек кысасы; *вставить в раму* — рамлап кую; рамга кую; 2. йөзлек, яңак; *рама у нар* — сәке йөзлеге; *рама ткацкого берда* — туку кылычы яңагы; 3. тәрәзә; *выставить зимние рамы* — икенче кат тәрәзәләрне алу; 4. *тех.* рам; *рама автомобиля* — автомобиль рамы; 5. *тех.* пычкы рамы (такта яру өчен берничә пычкыдан торган җайланма).

**РА'МКА** *ж.*— 1. кечкенә рам, рамка, кыса; *портрет в золоченой рамке* — алтынланган рамкадагы портрет; 2. *тех.* к. рама 4, 5; 3. *радио* рамлы антенна; 4. *перен. только мн.* чик; *не выходить из рамок приличия* — әдәп чикләреннән чыкмау (әдәп саклап эш итү). ◇ **Сновальная рамка** — буй җеп кысасы (туку станогында).

**РА'МНЫЙ** *спец.*— 1. тәрәзә...-ы, рам...-ы; *рамное стекло* — рам пыяласы, тәрәзә пыяласы; 2. рам (кыса) ясаучы; *рамный мастер* — рам (кыса) ясаучы оста.

**РАМОЛИ'** *нескл.*, **РАМО'ЛИК** *м. книж.*— 1. паралич суккан кеше; 2. *перен.* акылы чуалган, акыл сәләте йомшаган кеше; физик какшаган кеше, ватылган кеше.

**РАМОТЁС** *м. спец.*— кыса ясаучы, тәрәзә рамы ясаучы (оста яки эшче).

**РА'МОЧНИК** *м. спец.*— к. рамотёс.

**РА'МОЧНЫЙ** *спец.* — 1. к. рамный; 2. рамлы, кысалы; *рамочная антенна* — рамлы антенна (рам, кыса формасындагы антенна).

**РА'МПА** *ж.*— 1. *театр.* рампа (сәхнәне яктырту өчен сәхнә алдына тезелгән лампаларны каплап торган барьер); 2. *перен. театр.* сәхнә; *его пьеса так и не увидела рампы* — аның пьесасы тәки сәхнәгә менә алмады; 3. *тех.* рампа (метро поезды җир асты юлына кереп китә торган урындагы тимер-бетон корылма).

**РА'НА** *ж.*— 1. яра, җәрәхәт; *глубокая рана* — тирән яра; 2. *перен. книж. поэт.* газап, яра, кайгы, хәсрәт; *душевная рана*— йөрәк ярасы.

**РАНГ** *м. офиц.*— ранг, дәрәҗә; *капитан первого ранга (мор.)* — беренче ранг капитан; *крейсер первого ранга (мор.)*— беренче ранг (категория) крейсер. ◇ **Табель о рангах** *истор.*—чиннар (дәрәҗәләр) турында табель.

**РАНГО'УТ** *м. мор.*— рангоут (җилкәннәрне күтәрү, киерү, тотып тору һәм төшерү өчен хезмәт итә торган корылмалар җыелмасы — мачталар, аркылы агачлар һ. б.).

**РАНДЕВУ'** *ср. нескл. разг. шутл.*— күрешү, очрашу (күбрәк гашыйклар турында).

**РА'НЕ** *нареч. книж. устар.*— к. ранее.

**РАНЕВО'Й** *мед.*— яра...-ы; җәрәхәт...-ы; яраланган; *раневая поверхность* — яра есте, яраланган урын.

**РА'НЕЕ** *нареч. книж. устар.*— к. раньше.

**РАНЕ'НИЕ** *ср. книж. офиц.*— 1. *только ед.* яралану, җәрәхәтләнү; 2. яра, җәрәхәт; яраланган урын.

**РА'НЕНЫЙ** — 1. яралы, яраланган, җәрәхәтләнгән; *раненый Дубровский лежал на кровати* — яраланган Дубровский кроватьта ята иде; 2. *в знач. сущ., м.* яралы, яралы кеше; *в палате было трое раненых* — палатада өч яралы бар иде.

**РАНЕ'НЬКО** *нареч. разг. фам.*— бик иртә; иртүк, таң белән, иртә таңнан.

**РАНЕ'Т** *м.*— ранет (алма төре).

**РАНЁХОНЬКО** *нареч. разг. фам.*— к. ранёнько.

**РА'НЕЦ** *м.*— ранец, поход сумкасы; китап букчасы.

**РАНЁШЕНЬКО** *нареч. обл.*— к. ранёхонько.

**РАНЖИ'Р** *м. воен.*: **по ранжиру**— 1. *(расставить, выстроиться)* буйга, озынлыкка, зурлыкка карап (сафка тезү, тезелү); 2. *перен. (расположить)* әһәмиятенә, дәрәҗәсенә, чинына карап (урнаштыру); **под один ранжир** *(подвести) разг. шутл.*— барысын да бер хәлгә кую, барысын бер категориягә кертү; барысын бер тактага тезү, тигезләштерү.

**РА'НИТЬ** *сов.* и *несов.*— 1. яралау, җәрәхәтләү; *его ранили на войне* — аны сугышта яраладылар; 2. *перен. книж.* яралау, (йөрәккә) кадалу; газаплау, күңелне рәнҗетү; *его слова ранят сердце* — аның сүзләре йөрәккә кадала.

**РА'ННИЙ** *книж.*— 1. иртә, иртә башланган, иртә килгән, иртә төшкән; *ранняя осень* — иртә килгән көз; 2. вакытсыз, вакытыннан элек килгән; иртә килгән; *ранняя смерть* — вакытсыз үлем; 3. иртәнге; *в ранний час* — иртәнге сәгатьтә; 4. *перен. науч.* башлангыч, баштагы, тәүге, башлангыч чордагы; *ранний романтизм* — башлангыч романтизм. ◇ **Раннее яблоко** — иртә өлгерә торган алма. **Ранней весной** — яз башында. **Ранним утром** — иртә таңда, таң ату белән, иртүк. **Ранняя пташка** — таң кошы (иртә белән иртүк торып йөрүче кеше турында әйтелә). **Из молодых, да ранний** *разг. неодобр.*— яшь булса да, үзенә күрә түгел (артык масаючан яшь кеше турында әйтелә).

**РА'НО** *нареч.*— 1. иртә; *он лёг рано* — ул иртә ятты; 2. ... иртүк, ... алдыннан, ... башында ук; *рано весной* — яз башында ук; 3. бик иртә, вакытыннан элек; тиз; *он рано умер* — ул бик иртә үлде; *он рано состарился* — ул тиз картайды. ◇ **Раным-рано** *простореч.*— иртүк, иртә таңнан.

**РАНОВА'ТО** *нареч. разг. фам.*— иртәрәк, вакытыннан элегрәк; *рановато зима наступила* — кыш иртәрәк килде.

**РАНТ** *м. спец.*— 1. *сапож.* рант (итек олтанының читләренә тотылып чыккан күн кайма); *сапоги с рантом (на ранту)*— к. рантовой; 2. кайма, кырпу (берәр нәрсә тотылган кырый).

**РАНТОВО'Й** *спец. сапож.*— рантлы, каймалы; *рантовые сапоги* — рантлы күн итек.

**РАНТЬЕ'** *м. нескл. социол.*— рантье (капиталистик илләрдә рентага, ягъни беркайчан көч түкмичә, ссуда капиталыннан килгән доходка яшәүче сорыкорт).

**РАНЬ** *ж. мн.* нет, *простореч.*— бик иртә, иртә таң; *что ты в такую рань поднялся?*— нигә син бу кадәр иртә тордың?

**РА'НЬШЕ** *нареч.*— 1. *сравн. ст.* иртәрәк элегрәк, алданрак; *он встал рано, а я ещё раньше* — ул иртә торды, ә мин аннардан да иртәрәк тордым; 2. *(до срока)* элек, алда; әүвәлрәк; ...-ганга кадәр (чаклы, хәтле); ...-ганчы; *раньше, чем успел опомниться* — исенә килгәнгә чаклы (исенә килгәнче); 3. *(сначала)* башлап, башта, алдан, әүвәл, (иң) элек; *раньше выслушай, а потом говори* — элек тыңлап бетер, аннары сөйлә; 4. *разг.* элек(тә), элекке вакытта, элгәре, бер вакыт; *раньше мы были друзьями* — элек без дус идек.

**РАПИ'РА** *ж. спорт.*— рапира (фехтованиедә кулланыла торган дүрт кырлы махсус спорт кылычы).

**РА'ПОРТ** *м. офиц.*— рапорт (эшләнгән эш, урындагы хәл турында телдән яки язма рәвештә югары инстанциягә бирелә торган мәгълүмат).

**РАПОРТОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. офиц.*— рапорт бирү; (хәл турында) белдерү, хәбәр итү; *рапортовать о выполнении плана* — планның үтәлүе турында белдерү.

**РАПОРТОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов. офиц.*—

1. *воен. устар.* үзе турында белдерү, рапорт бирү; *он рапортовался больным* — ул үзен авыру дип белдерде; 2. *страд.* рапорт бирелү, хәбәр ителү, белдерелү.

**РАПС** *м.*— рапс (орлыгыннан май чыгарыла торган үсемлек).

**РАПСО'Д** *м. истор.*— рапсод, илгизәр жырчы (борынгы Грециядә халык дастаннарыннан аерым өлешләрне жырлап йөрүче).

**РАПСО'ДИЯ** *ж.*— рапсодия (1. *истор.* борынгы грекларда илгизәр жырчылар тарафыннан башкарылган эпик жыр өзекләре; 2. *муз.* халык легендалары темасына язылган һәм төрле-төрле өлешләрдән торган зур музыкаль әсәр).

**РАРИТЕ'Т** *м. книжн.*— сирәк әйбер (кыйммәтле һәм сирәк табыла торган әйбер).

**РА'СА** *ж.*— раса (тарихи-географик нигездә формалашкан икенче дәрәжәдәге тышкы билгеләр: баш сөягенең формасы, тән, күз һәм чәчләренең төсе һ. б. ш. буенча шартлы рәвештә бүленә торган кешеләр группасы).

**РАСИ'ЗМ** *м. мн.* нет — расизм, расачылык (кешелек дөньясындагы төрле расаларның акыл һәм культура үсеше ягыннан сәләтлекләре бертигез дәрәжәдә түгел, дип әйрәтә торган, фәнгә каршы, реакционфашистик тәгълимат).

**РАСИ'СТ** *м.*— расачы, расизм тарафдары.

**РАСИ'СТСКИЙ** — расачылык...-ы; расачылар...-ы; *разоблачать расистские теории* — расачылык теорияләрен фаш итү.

**РАСКАБАЛИ'ТЬ** *сов.*— азат итү, иреккә чыгару, коллыктан коткару, кабаладан котылдыру.

**РАСКАБАЛИ'ТЬСЯ** *сов.*— кабаладан чыгу, азат булу, боеңдырыктан котылу, богаудан ычкыну, коллыктан котылу.

**РАСКАБАЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. раскабалить.

**РАСКАБАЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. раскабалиться; 2. *страд.* азат ителү; кабаладан чыгарылу, коллыктан коткарылу.

**РАСКА'ИВАТЬСЯ** *несов.*— к. раскаяться.

**РАСКАЛЁННЫЙ** — 1. кызган, кыздырылган; утлы, уттай кызган; *раскалённый металл* — уттай кызган металл; 2. кызу, эссе, кайнар; *раскалённый воздух* — эссе һава.

**РАСКАЛИ'ТЬ** *сов.*— кыздыру, бик нык кыздыру; эсселәтү (һаваны); *раскалить утюг* — үтүкне кыздыру.

**РАСКАЛИ'ТЬСЯ** *сов.*— бик нык кызу, уттай кызу, ут булу; эсселәнү (һава), кайнарлану (ком).

**РАСКА'ЛЫВАТЬ** *несов.*— к. расколоть.

**РАСКА'ЛЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. расколоться.

**РАСКАЛЯ'КАТЬСЯ** *сов. просторечн. фам.* — сүзгә мавыгып китү, гәпләшеп китү.

**РАСКАЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. раскалить.

**РАСКАЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. раскалиться; 2. *страд.* бик нык кыздырылу.

**РАСКА'ПЫВАТЬ** *несов.*— к. раскопать.

**РАСКА'ПЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— казылу, казып алыну, казып чыгарылу, казып табылу.

**РАСКА'РМЛИВАТЬ** *несов.*— к. раскормить.

**РАСКА'РМЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— симергәнче ашатылу, симертелү, көрәйтелү.

**РАСКАРЯ'КА** *ж. просторечн.*— к. раскоряка.

**РАСКАРЯ'ЧИТЬ** *сов.*— к. раскорячить.

**РАСКАРЯ'ЧИТЬСЯ** *несов.*— к. раскорячиться.

**РАСКАССИ'РОВАТЬ** *сов.*— 1. *воен. устар.* к. расформировать; 2. *перен. разг.* бетерү, тарату; *раскассировать комиссию* — комиссияне тарату.

**РАСКА'Т** *м.*— 1. *только ед. спец.* к. раскатать 1, 2, 3, 4; 2. *только ед. спец.* к. раскатить; 3. *обл.* кагылма, салу; *ухабы и раскаты делают зимние дороги едва проезжими* (Даль) — сикәлтәләр һәм салулар кышкы юлларда йөрүне бик кыенлаштыралар; 4. *спец.* тизлек, кызулап китү (мәс., чанада барганда яки шуганда); 5. гөрелдәү, гөрселдәү, гөрелте; яңгырау тавышы; *раскаты грома* — күк күкрәү тавышлары; 6. *лингв.* калтырау тавышы (мәсәлән, „р" авазын әйткәндә).

**РАСКАТА'ТЬ** *сов.*— 1. тарату, таратып җәю, җәеп җибәрү; *раскатать ковёр* — паласны таратып җәю; 2. *разг.* (төрле якка) тәгәрәтү; *раскатать сложенные брёвна* — өелгән бүрәнәләрне төрле якка тәгәрәтү; 3. *спец.* (юлны) тигезләү, такырайту; (сырлы бәләк белән кер) тәгәрәтү; 4. җәю, әвәләп җәю; *раскатать тесто* — камыр җәю; 5. *просторечн. фам.* (*разбранить*) бик нык сүгү, бик каты әрләү, бик каты тиргәү, тиргәп ташлау; шелтәләү.

**РАСКАТА'ТЬСЯ** *сов.*— 1. таралу, җәелү, таралып китү, сүтелеп китү; *свёрнутый бинт раскатался* — уралган бинт сүтелеп китте; 2. *спец.* әвәләнеп җәелү, җәелеп (юкарып) җитү; *тесто раскаталось* — камыр җәелде; 3. *фам.* бик озак шуу, шуу белән мавыгу, шууга бирелеп китү.

**РАСКА'ТИСТО** *нареч.*— шаркылдап, яңгыратып; *раскатисто смеяться* — яңгыратып көлү.

**РАСКА'ТИСТЫЙ** *разг.*— 1. яңгыравыклы, гөрелдәүле; гөрелдәгән; *раскатистый голос* — яңгыравыклы тавыш; 2. шаркылдап...; яңгыратып..., кыткылдап...; *раскатистый хохот* — шаркылдап көлү; 3. салулы, кагылмалы (юл). ◇ **Раскатистые согласные** *лингв.*— калтыраулы тартыклар (мәсәлән, „р" авазы).

**РАСКАТИ'ТЬ** *сов.*— 1. бик кызу (тиз) әйләндерә башлау, әйләндереп җибәрү; әйләндерә-әйләндерә тизләтү, кыздырып җибәрү; *раскатить колесо* — тәгәрмәчне бик кызу әйләндереп җибәрү (ягъни бик кызу әйләндерә башлау); 2. төрле якка тәгәрәтү, тәгәрәтеп җибәрү, тәгәрәтеп таратып ташлау; *раскатить сложенные брёвна* — өелгән бүрәнәләрне төрле якка тәгәрәтеп җибәрү.

**РАСКАТИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. тәгәри-тәгәри кызып китү; кызу шуып китү, кызулап китү;

кызу әйләнә башлау, кызу тәгәрәп китү; *салазки раскатились с горы* — кечкенә чана таудан бик кызу шуып китте; 2. төрле якка тәгәрәп китү, таралып китү; *брёвна раскатились* — бүрәнәләр тәгәрәп таралып киттеләр; 3. салулау, салулап китү, *сани раскатились* — чана салулап китте.

**РАСКА'ТКА** *ж. спец.* — 1. к. раскатать; 2. (*скалка*) уклау.

**РАСКА'ТЫВАТЬ** *несов.* — 1. к. раскатать; 2. к. раскатить; 3. *разг.* күп йөрү, чабып йөрү (атта, машинада һ. б. ш.); кататься итеп йөрү; *весь день раскатывает по городу* — көне буе шәһәр буенча чабып йөри.

**РАСКА'ТЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. раскататься; 2. к. раскатиться; 3. *страд.* тәгәрәтеп җәелү, таратып җәелү, сүтелү; төрле якка тәгәрәтеп җибәрелү (бүрәнәләр), тәгәрәтеп тигезләтелү, такырайтылу (каток, сырлы бәләк һ. б. белән); әвәләнү, җәелү (камыр).

**РАСКАЧА'ТЬ** *сов.* — 1. тирбәтү, тирбәлдерү, атындыру, чайкалдыру (як-якка); кузгатып (селкетеп) җибәрү; тирбәтеп (атындырып) җибәрү; *раскачать качели* — таганны атындырып җибәрү; 2. *простореч.* (*расшатать*) селкетеп какшату, бушайту; 3. *перен. разг.* (берәр эшкә) кузгатып җибәрү; дәртләндерү, җилкендерү; *его трудно раскачать, очень уж тяжёл на подъём* — аны кузгатып җибәрүе кыен, бик инде авыр сөякле.

**РАСКАЧА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. тирбәлә (селкенә) башлау; нык чайкала башлау; *маятник раскачался* — маятник тирбәлә башлады; 2. бик нык атына башлау, бик шәп атынып китү; 3. *разг. фам.* бик озак атыну, бик күп атыну, атыну белән мавыгып китү; 4. *разг.* селкенә башлау, какшый башлау; *столб раскачался* — багана селкенә башлады. ◇ **Трудно раскачаться, а там пошёл** — эшкә керешүе генә авыр, аннан соң шәп бара.

**РАСКА'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. раскачать.

**РАСКА'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. раскачаться; 2. *простореч.* (*о походке*) алпан-тилпән (чайкалып) йөрү; 3. *страд.* чайкалдырылу, тирбәтелү, селкендерелү; атындырып җибәрелү. ◇ **Раскачивайся!** — селкенә төш! кызурак кыймылда!

**РАСКА'ЧКА** *ж. простореч.* — 1. *только ед. к.* раскачать; 2. к. раскачаться; 3. *обл.* (*о походке*) алпан-тилпән йөреш. ◇ **Действовать, не теряя времени на раскачку** — бушка вакыт үткәрми эшкә керешү.

**РАСКА'ШИВАТЬ** I *несов.* — к. раскосить I.

**РАСКА'ШИВАТЬ** II *несов.* — к. раскосить II.

**РАСКА'ШИВАТЬСЯ** I *несов. страд.* — терәү салыну (куелу), терәү белән ныгытылу.

**РАСКА'ШИВАТЬСЯ** II *несов. обл.* — к. раскоситься.

**РАСКА'ШЛИВАТЬСЯ** *несов.* — к. раскашляться.

**РАСКА'ШЛЯТЬСЯ** *сов.* — бик нык йөткерә башлау, туктаусыз ютәлли башлау; туктаусыз йөткерену; *больной раскашлялся* — авыру туктаусыз ютәлли башлады.

**РАСКА'ЯНИЕ** *ср. мн.* нет — үкенү, үкенеч; тәүбә, офтану; *достойный раскаяния* — үкенерлек, үкенечле; *чувствовать раскаяние* — күңел ачыну, офтану.

**РАСКА'ЯТЬСЯ** *сов.* — үкенү, тәүбә итү, офтану; *раскаяться в преступлении* — эшләгән җинаяте өчен тәүбә итү.

**РАСКВАРТИРОВА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *офиц.* — квартирларга урнаштыру, квартирларга урнашу; квартирларга урнаштырылу.

**РАСКВАРТИРОВА'ТЬ** *сов. офиц.* — квартирларга урнаштыру, квартирларга тарату, фатирга кую (мәс., гаскәрне).

**РАСКВАРТИРОВА'ТЬСЯ** *сов. офиц.* — квартирларга урнашу, фатирга керү.

**РАСКВАРТИРО'ВЫВАТЬ** *несов. офиц.* — к. расквартировать.

**РАСКВАРТИРО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. офиц.* — 1. к. расквартироваться; 2. *страд.* квартирларга урнаштырылу.

**РАСКВА'СИТЬ** *сов. простореч.* — сугып җимерү; сугып яру; сугып канату, канга батыру; *расквасить нос* — борынын җимерү.

**РАСКВА'ШИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. расквасить.

**РАСКВИТА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. (*покончить расчёты*) исәп-хисапны өзү, үзара исәпне өзү; эшне бетерү; өзелешү; 2. *перен.* (*отплатить за обиду*) үч алу, үч кайтару, исәпләшү.

**РАСКИДА'ТЬ** *сов. разг.* — к. разбросать.

**РАСКИДА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — к. разбросаться.

**РАСКИ'ДИСТЫЙ** *разг.* — киң җәелеп (таралып) үскән; тармакланып үскән; ботаклары киң җәелгән, киң ябалдашлы, тармаклы-тармаклы; *раскидистый вяз* — киң җәелеп үскән карама агачы.

**РАСКИДНО'Й** *спец.* — җәелмәле; ачып зурайтыла торган; *раскидной стол* — ачып зурайтыла торган өстәл. ◇ **Раскидная карета (или ландо)** *устар.* — өсте ачылмалы карета.

**РАСКИ'ДЧИВО** *нареч. разг.* — таркау гына, игътибарсыз, сибелеп-чәчелеп; *в начале говорили раскидчиво* — башта таркау гына сөйләделәр.

**РАСКИ'ДЧИВЫЙ** *разг.* — таркау.

**РАСКИ'ДЫВАТЬ** *несов.* — 1. *разг.* к. раскидать; 2. к. раскинуть.

**РАСКИ'ДЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг.* к. раскидаться; 2. к. раскинуться 1, 2; 3. *спец.* ачылу, җәелү, ачылмалы (җәелмәле) булу; 4. *страд.* туздырылу, таратылу; туздырып ташлану; 5 *страд.* корылу; *палатки раскидываются экскурсантами* — чатырлар экскурсантлар тарафыннан корыла.

**РАСКИ'НУТЬ** *сов.* — 1. җәю, җәеп ташлау; җәеп кую, ачып җибәрү; *раскинуть руки, ноги* — аяк-кулларын җәеп ташлау; 2. (җәеп) салу, таратып ташлау; *раскинуть невод* — җылымны җәеп салу (балык тоту яки киптерү өчен); 3. җәелү, урын алу; *Волга раскинула свои притоки по обширной равнине* — Волга үзенең кушыл-

дыклары белән киң тигезлеккә җәелгән; 4. *перен. книжн.* җәеп җибәрү, киңәйтү, җәелдерү; *нужно шире раскинуть сеть колхозной торговли* — колхоз сәүдәсе челтәрен киң җәелдерергә кирәк; 5. кору, корып кую; *раскинуть шатёр* — чатыр кору; 6. җәеп кую, ачып киңәйтү; *раскинуть походную кровать* — поход кроватен җәеп кую. ◇ **Раскинуть умом (или мозгами)** *разг.*— башны уйлату, исәпләп (уйлап) карау; акыл йөртеп карау, акылны эшкә җигеп карау.

**РАСКИ'НУТЬСЯ** *сов.*— 1. *разг.* сузылып яту, җәелеп яту, киерелеп яту; 2. *перен.* җәелеп китү; сибелеп урнашу, җәелеп утыру, сузылып китү (мәс., авыл); урнашу (мәс., лагерь); 3. *перен.* киң таралу, киң җәелү; *по всей советской стране раскинулась сеть библиотек* — бөтен совет иле буенча китапханәләр челтәре киң җәелде.

**РАСКИПЕ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. бик нык кайнау, бик нык кайный башлау; *чайник раскипелся* — чәйнек бик нык кайный башлады; 2. *перен.* к. раскипятиться.

**РАСКИПЯТИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — бик нык кызып (ярсып, дулап) китү, кабынып китү, бик нык чәпчеп китү; *раскипятился и на всех накричал* — кызып китеп барысын да орышып ташлады.

**РАСКИСА'ТЬ** *несов.*— к. раскиснуть.

**РАСКИ'СЛЫЙ** *разг.*— әлсерәгән, мәлҗерәгән; арыган, хәлдән тайган, изрәп төшкән, җебегән; ялкауланган, дәртсезләнгән.

**РАСКИ'СНУТЬ** *сов.*— 1. *спец.* әчү, әчеп бетү, ачып чыгу, ачып кабару; *тесто раскисло* — камыр ачып кабарган; 2. *перен. разг. фам.* изрәп төшү, әлсерәү, хәлсезләнү, хәлдән таю, алҗу; *совсем раскис от жары* — эсседән тәмам әлсерәде; 3. *перен. разг. фам.* җебеп төшү, мәлҗерәү, дәрт сүнү, ялкаулык басу; *он совсем раскис* — ул бөтенләй җебеп төшкән.

**РАСКЛА'Д** *м. спец.*— өләшү, тарату; таратылыш, салыныш, бүленеш (уен картасы һ. б. турында).

**РАСКЛА'ДКА** *ж.*— 1. *только ед.* к. разложить I; 2. бүлешү, салышу; 3. *спец.* к. расклал; 4. *тип.* биткә салыныш.

**РАСКЛАДНО'Й** *спец.*— җәелмәле, ачылмалы, сүтелмәле; *раскладной стол* — җәелмәле өстәл.

**РАСКЛА'ДОЧНЫЙ**— бүлгәннән соң тигән; өстәмә; *раскладочный сбор* — өстәмә җыем.

**РАСКЛАДУ'ШКА** *ж.* — җәелмә кровать (җәелә һәм җыела торган кровать).

**РАСКЛА'ДЫВАТЬ** *несов.*—к. разложить I.

**РАСКЛА'ДЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. разложиться I; 2. *страд.* аеры-аеры куелу, урыны-урынына куеп чыгылу, урнаштырылу; (билгеле бер тәртиптә) тезелү, таратылу, таратып салыну; бүленү, салыну (салым); җәелү (урын-җир); ягылу (ут).

**РАСКЛА'НИВАТЬСЯ** *несов.* — к. раскланяться. ◇ **Перестать раскланиваться** (*с кем*) — исәнләшми (сәлам бирми) башлау; дуслыкны өзү.

**РАСКЛА'НЯТЬСЯ** *сов.*— 1. (*при встрече*) баш иеп күрешү, исәнләшү, сәламләшү; (*при расставании*) хушлашу, саубуллашу; 2. *перен. разг. ирон.* бәхилләшү.

**РАСКЛА'СТЬ** *сов. простореч.*— к. разложить I.

**РАСКЛЕВА'ТЬ** *сов.*— 1. чукып ашап бетерү, чукып тишкәләп бетерү; 2. *перен. разг.* юк итү, бетерү, чукып бетерү; *его там расклевали бы* — анда аны чукып бетерерләр иде (юл бирмәсләр иде).

**РАСКЛЁВЫВАТЬ** *несов.*—к. расклевать.

**РАСКЛЕ'ИВАТЬ** *несов.*— к. расклеить.

**РАСКЛЕ'ИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. расклеиться; 2 *страд.* куптарып алыну, куптарып чыгарылу, куптарылу.

**РАСКЛЕ'ИТЬ** *сов.*— 1. ябышканны куптару, куптарып чыгару, куптарып (аерып) алу; ачу; 2. (төрле урыннарга) ябыштырып чыгу; *расклеить афиши* — (төрле урыннарга) афишалар ябыштырып чыгу.

**РАСКЛЕИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. кубу, кубып чыгу, кубып төшү, кубып таралу; *стул расклеился* — урындык кубып чыкты; 2. *перен. простореч.* сүтелү, таралу, бозылу, җимерелү, барып чыкмау; *сделка расклеилась* — эш барып чыкмады; 3. *перен. разг. фам.* авырып китү, эштән чыгу, хәлсезләнү, дәртсезләнү.

**РАСКЛЕ'ЙКА** *ж. мн.* нет—к. расклеить 2.

**РАСКЛЕ'ЙЩИК** *м.*, **РАСКЛЕ'ЙЩИЦА** *ж. спец.* — белдерү (игълан, афиша) ябыштыручы.

**РАСКЛЕПА'ТЬ** *сов. спец.*— (заклёпкаларын чыгарып) кисәкләргә аеру, кисәкләргә таратып ташлау, сүтү; *расклепать котёл* — заклёпкаларын чыгарып казанны кисәкләргә аеру (сүтү).

**РАСКЛЕПА'ТЬСЯ** *сов. спец.*— (заклёпкалары төшеп, кубып) таралу, кисәкләргә аерылу; *котёл расклепался* — казанның заклёпкалары кубып таралган.

**РАСКЛЁПКА** *ж. мн.* нет, *спец.*— к. расклепать.

**РАСКЛЁПЫВАТЬ** *несов. спец.*— к. расклепать.

**РАСКЛЁПЫВАТЬСЯ** *несов. спец.*— 1. к. расклепаться; 2. *страд.* (заклёпкасы алынып) кисәкләргә таратылу.

**РАСКЛИ'НИВАТЬ** *несов. спец.*— к. расклинить.

**РАСКЛИ'НИВАТЬСЯ** *несов. спец.*— 1. к. расклиниться; 2. *страд.* чөе алыну, чөе чыгарылу.

**РАСКЛИ'НИТЬ** *сов. спец.*— 1. чөен чыгару; 2. чөй кагып яру, чөй белән яру.

**РАСКЛИ'НИТЬСЯ** *сов. спец.*— чөй каккannан ярылу, чөй кагып ярылу.

**РАСКО'ВАННЫЙ** — 1. чүкелгән; (чүкеп) яньчелгән, юкартылган; 2. дагасыз, дагасы алынган; 3. богаусыз, богавы салдырылган, богаудан коткарылган (ычкындырылган).

**РАСКОВА'ТЬ** *сов.*— 1. (*о лошади*) дагасын алу; 2. (*о закованном человеке*) богавын алу, богавын салдыру; 3. *спец.* чүкеп юкарту, яньчү, җәю.

**РАСКОВА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. (*о лошади*) дагасы төшеп калу, дагасын югалту; 2. (*о человеке*) богаудан котылу, богавын салу.

**РАСКО'ВКА** *ж. мн.* нет, *спец.*— к. расковать.

**РАСКО'ВЫВАТЬ** *несов.*— к. расковать.

**РАСКО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. расковаться; 2. *страд.* дагасы алыну; 3. *страд.* богаудан ычкындырылу, богавы салдырылу.

**РАСКОВЫ'РИВАТЬ** *несов. разг.*— к. расковырять.

**РАСКОВЫ'РИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— чокып (тырнап) чыгарылу.

**РАСКОВЫРЯ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. чокып чыгару, чокып тишеп чыгару; чокып киңәйтү, чокып зурайту; *расковырять дыру в стене* — стенадагы тишекне чокып киңәйтү; 2. тырнап бетерү, сыдырып чыгару; тырнап аздыру (яраны, шешне).

**РАСКО'КАТЬ** *сов. просторец. фам.* — төшереп вату, бәреп вату.

**РАСКО'Л** *м.*— 1. *спец.* к. расколоть 1; 2. *полит.* раскол, аерылу, таркалу (бер партия яки оешманың фикер башкалыклары нәтиҗәсендә ике капма-каршы өлешкә бүленүе); 3. *только ед. церк. истор.* раскол, мәзһәп-секталарга аерылу (XVII йөздә Россиядә барлыкка килгән дини хәрәкәт).

**РАСКОЛА'ЧИВАТЬ** *несов.*— к расколотить.

**РАСКОЛА'ЧИВАТЬСЯ** *несов.*— к. расколотиться.

**РАСКОЛОТИ'ТЬ** *сов.*—1. (*о сколоченном*) суккалап вату, суккалап сүтү; ватып ташлау; *расколотить ящик* — ящикны вату (суккалап); 2. *спец. сапож.* тукмап җәю, яньчү; тукмаклап сузу, зурайту, киңәйтү (аяк киемен калыпта тукмаклап); 3. *просторец. фам.* вату, ваклау; *расколотить тарелку* — тарелканы вату; 4. *просторец. вульг.* тукмау, җимерү, төю, изү; тукмап имгәтү; 5. *разг.* тукмау, тәпәләү, тар-мар итү; *расколотить неприятеля*—дошманны тармар итү.

**РАСКОЛОТИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. (бәрелү-сугылудан) җимерелү, таралу, ватылу, таралып китү; *ящик расколотился в пути* — ящик юлда барганда ватылган; 2. *спец. сапож.* (тукмаклаудан) киңәю, зураю, сузылу, җәелү; 3. *просторец. фам.* (*о посуде*) ватылу, уалу, челпәрәмә килү.

**РАСКО'ЛОТЫЙ** — ярылган, ватык, ватылган, ваткан, вакланган; *расколотый сахар* — ваткан шикәр.

**РАСКОЛО'ТЬ** *сов.*— 1. яру, вату, ваклау; *расколоть полено* — утын агачын яру; *расколоть сахар* — шикәр вату; 2. *перен.* аеру, таркату, бердәмлекне бозу, араны бозу, низаг салу.

**РАСКОЛО'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *разг.* ярылу, ватылу, ваклану; ярылып китү; 2. *перен.* (*распасться*) аерылу, бүленү, таркалу.

**РАСКОЛУПА'ТЬ** *сов. просторец.* — тырнап (чокып, сыдырып) тишү, тырнап бетерү; тырнап кубарып алу; *расколупать ранку*— яраны тырнап бетерү.

**РАСКОЛУ'ПЫВАТЬ** *несов. просторец.*— к. расколупать.

**РАСКОЛЫХА'ТЬ** *сов.*— 1. бик нык чайкалдыру, селкетү; бик нык тибрәтү, җилфердәтү; җилфердәтеп (селкетеп, чайкалдырып) җибәрү; *ветер расколыхал знамёна* — җил байракларны җилфердәтеп җибәрде; 2. дулкын куптару, дулкынлатып җибәрү; *ветер расколыхал море* — җил диңгездә дулкыннар куптарды; 3. *перен. разг.* дулкынландыру, хәрәкәткә китерү, кузгатып җибәрү; *расколыхать массы* — массаларны кузгатып җибәрү.

**РАСКОЛЫХА'ТЬСЯ** *сов.*— 1. бик нык чайкалу, чайкала башлау; бик нык дулкынлану, дулкынланып китү; айкалу-чайкалу, *море синее расколышется* (Даль) — зәңгәр диңгез айкалыр-чайкалыр; 2. *перен. разг.* кузгалу, хәрәкәткә килү; *массы расколыхались* — массалар кузгалды.

**РАСКО'ЛЬНИК** *м.*, **РАСКО'ЛЬНИЦА** *ж.*— 1. *церк.* раскольник, сектант (аерым бер дини мәзһәптә торучы); 2. *перен. полит. неодобр.* таркатучы, расколчы, раскол тудыручы, раскол ясарга котыртучы.

**РАСКО'ЛЬНИЧЕСКИЙ** *книж.* — 1. *церк.* раскольниклар...-ы; *раскольническая молельня* — раскольниклар гыйбадәтханәсе; 2. *полит. неодобр.* раскол ясау (тудыру)...-ы; расколчылык...-ы, таркату...-ы; *раскольническая тактика* — раскол тудыру тактикасы (расколчылык тактикасы).

**РАСКО'ЛЬНИЧИЙ** *религ.*— к. раскольнический 1.

**РАСКО'ЛЬЩИК** *м.*—1. *обл.* к. раскольник 1; 2. *разг. неодобр.* к. раскольник 2.

**РАСКОНОПА'ТИТЬ** *сов. спец.*— сүсен алу, мүген алу, (тишек-ярыкларга тыгылган мүк, киез, сүсне) алып ташлау.

**РАСКОНОПА'ЧИВАТЬ** *несов. спец.*— к. расконопатить.

**РАСКОНСЕРВИ'РОВАТЬ** *сов. спец.* — яңадан эшләтә башлау (вакытлыча эштән туктатылган предприятие турында).

**РАСКОПА'ТЬ** *сов.*— 1. казу, казып (таратып) ташлау, казып бетерү; *раскопать землю* — җирне казып ташлау; 2. казып табу, казып ачу; казып чыгару; *раскопали пласт угля* — күмер катлавы ачканнар; 3. *перен. разг.* казып чыгару, чокчынып (тәпченеп, тикшереп) белү; *суд всё раскопает* — суд барын да казып чыгарыр (тикшереп белер); 4. *перен. разг. фам.* (*отыскать*) актарып (эзләп) табу.

**РАСКО'ПКА** *ж.*— 1. *только ед.* к. раскопать; 2. *только мн.* казу эшләре, казып алу эшләре, казып эзләү эшләре; *раскопки клада* — хәзинә казу эшләре. ◇ **Археологические раскопки** — археологик казылмалар, археологик казылмалар үткәрү (җир астыннан борынгы заман әйберләрен казып чыгару эшләре).

**РАСКОРМИ'ТЬ** *сов. разг.*— ашатып симертү, көрәйтү, симергәнче ашату.

**РАСКО'РМЛЕННЫЙ** — 1. ашатып симертелгән; 2. симез, көр; симергән, көрәйгән, симереп җиткән.

**РАСКОРЧЕВА'ТЬ** *сов. спец.* — төп чистарту, ышна ачу (җирне төпләрдән арчып бетерү).

**РАСКОРЯ'КА** *м.* и *ж. простореч.*— 1. камыт аяк, чалыш аяк (аякларын бик нык аерып атлаучы кеше); 2. *перен.* булмаган кеше, эш рәтен белмәүче.

**РАСКОРЯ'ЧИВАТЬ** *несов. простореч.*— к. раскорячить.

**РАСКОРЯ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. простореч.*— к. раскорячиться.

**РАСКОРЯ'ЧИТЬ** *сов. простореч.*—аеру, еру, җәю; *раскорячить ноги* — аягын аеру.

**РАСКОРЯ'ЧИТЬСЯ** *сов. простореч.*—аякны аеру, аякларны аерып басу (аерып яту).

**РАСКО'С** *м. спец.*— кыек терәткеч, кыек терәү.

**РАСКОСИ'ТЬ** I. *сов.*— 1. *спец.* терәү салу, терәү кую, терәтү; кыек терәү белән ныгыту; 2. *простореч. (о глазах)* кылыйлату, чалшайту, күзнең икесен ике якка карату.

**РАСКОСИ'ТЬ** II *сов. обл.* — бергәләп чабып бетерү, урып бетерү (печәнне яки игенне).

**РАСКОСИ'ТЬСЯ** *сов. обл.*— чабу (уру) белән мавыгып китү; бик кызу чаба башлау (мәсәлән, печәнне).

**РАСКО'СОСТЬ** *ж. мн.* нет — чалыш күзлелек, кылыйлык, кылый күзлелек, күзләре ике якка караганлык.

**РАСКО'СЫЙ** — кылый күзле, чалыш күзле, (күзе) ике якка караган; *раскосые глаза* — ике якка караган күзләр (берсе мәгърипкә, берсе мәшрикъкә караган күзләр).

**РАСКОШЕ'ЛИВАТЬСЯ** *несов. простореч.*— к. раскошелиться.

**РАСКОШЕ'ЛИТЬСЯ** *сов. простореч.*— янчыкны ачу (бушату); акча тоту, акча түздыра башлау; юмартланып китү.

**РАСКРА'ДЫВАТЬ** *несов.*— к. раскрасть.

**РАСКРА'ДЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— урлану, урлап алыну, урланып бетү.

**РАСКРА'ИВАТЬ** *несов.*— к. раскроить.

**РАСКРА'ИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— үлчәп киселү, киемгә киселү (киемлек материя турында).

**РАСКРАСА'ВЕЦ** *м. простореч.*— чибәр кеше, бик матур кеше; *раскрасавец ты мой!* — чибәрем син! матурым син!

**РАСКРАСА'ВИЦА** *ж. простореч.*— сылу кыз, матур (гүзәл, зифа) кыз; чибәр хатын, матур хатын; *у окна раскрасавица сидит* — тәрәзә каршында бер сылу кыз утыра.

**РАСКРА'СИТЬ** *сов.*— буяу, бизәү, буяп чыгу, буяп бетерү; матурлап буяу, төрле төскә буяу (төрле буяулар белән).

**РАСКРА'СИТЬСЯ** *сов.*— 1. (төрле төскә) буялу, бизәлү, буяп чыгылу, буяп бетерелү; төрле төскә керү; 2. *простореч. фам.* артык буяну, артык бизәнү, артык ягыну; буяу (бизәү) белән мавыгып китү.

**РАСКРА'СКА** *ж. мн.* нет — 1. *разг.* к. раскрасить; 2. к. расцветка.

**РАСКРАСНЕ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. бик нык кызару, бик нык кызарып китү, кып-кызыл булу; аллану, алсулану; *раскраснеться от смущения* — оялудан кып-кызыл булу.

**РАСКРА'СТЬ** *сов. разг.*— урлап бетерү, урлап китү, талап чыгу (бар нәрсәсен дә).

**РАСКРА'СЧИК** *м. спец.*— буяучы (эшче, оста).

**РАСКРА'ШИВАНИЕ** *ср. мн.* нет — төрле төскә буяу, буяп чыгу; *картинки для раскрашивания* — төрле төскә буяу өчен эшләнгән рәсемнәр (балалар өчен махсус китапчыклар).

**РАСКРА'ШИВАТЬ** I *несов.*— к. раскрасить.

**РАСКРА'ШИВАТЬ** II *несов. разг.*— к. раскрошить.

**РАСКРА'ШИВАТЬСЯ** I *несов.*— к. раскраситься 1.

**РАСКРА'ШИВАТЬСЯ** II *несов. разг.*— к. раскрошиться.

**РАСКРЕПИ'ТЬ** I *сов. спец.* — (терәвен) аерып алу, аеру.

**РАСКРЕПИ'ТЬ** II *сов. спец.*— (терәүләр белән) ныгыту, ныгытып кую.

**РАСКРЕПИ'ТЬСЯ** *сов. спец.* — (терәве) аерып алыну, аерылып чыгу; беркеткәне аерылу, ныгытканы бушау.

**РАСКРЕПЛЯ'ТЬ** *несов. спец.*— к. раскрепить.

**РАСКРЕПЛЯ'ТЬСЯ** *несов. спец.*— 1. к. раскрепиться; 2. *страд.* (терәүләр белән) ныгытылу, ныгытып куелу.

**РАСКРЕПОСТИ'ТЬ** *сов. книж.*—1. *истор.* крепостнойлыктан коткару, крепостной боендырыктан азат итү (крестьяннарны); 2. *перен. публиц.* ireккә чыгару, азатлыкка чыгару; коллыктан (изелүдән) коткару; *Советская власть раскрепостила женщину* — Совет власте хатын-кызларны азатлыкка чыгарды.

**РАСКРЕПОСТИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. *истор.* крепостнойлыктан котылу, крепостнойлыктан азат булу; 2. *перен.* ирекkә (азатлыкка) чыгу; изелүдән (коллыктан) котылу.

**РАСКРЕПОЩА'ТЬ** *несов.*— к. раскрепостить.

**РАСКРЕПОЩА'ТЬСЯ** *несов.*— к. раскрепоститься.

**РАСКРЕПОЩЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — к. раскрепостить, раскрепоститься; *раскрепощение крестьян* — крестьяннарның крепостнойлыктан азат ителүе.

**РАСКРЕПОЩЁННЫЙ** — 1. крепостнойлыктан азат ителгән; 2. *перен.* азат, ирекле, хөр; *раскрепощённый труд* — азат хезмәт.

**РАСКРИТИКОВА'ТЬ** *сов.*— бик каты тәнкыйтьләү, бик каты тәнкыйть итү, тәнкыйть астына алу, тетеп салу, тетеп ташлау, яраксызга чыгару (тәнкыйтьләп).

**РАСКРИТИКО'ВЫВАТЬ** *несов.*— к. раскритиковать.

**РАСКРИЧА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. *(поднять крик)* каты кычкыра башлау, тавыш (гаугa) куптару, шау-шу күтәрү; 2. (*наброситься с руганью*) җикерену, акырыну.

**РАСКРОИ'ТЬ** *сов.*— 1. *порт.* кием кисү; үлчәп кисеп чыгу, өлгеләп кисеп кую (киемлек әйбер турында); 2. *разг.* сугып яру, ярып чыгару.

**РАСКРО'Й** *м.*, **РАСКРО'ЙКА** *ж. порт.*—

1. *только ед.* к. раскроить 1; 2. *(способ кройки)* киселеш, киселү рәвеше, кием кисү ысулы; *(фасон покроя)* тегелеш, тегелү рәвеше (фасоны).

**РАСКРОМСА'ТЬ** *сов.*— 1. ботарлап (өзгәләп, кисәкләп) бетерү; тураклап (телгәләп, ваклап) ташлау; 2. *порт.* кискәләп бетерү, кисәк-косак кисеп бозып бетерү (мәсәлән, материяне); 3. *перен.* (кискәләп, сызгалап) бозып бетерү (мәсәлән, әсәрне).

**РАСКРОШИ'ТЬ** *сов.*— турау, тураклау, ваклау; тураклап (ваклап, валчыклап) бетерү; *раскрошить хлеб* — ипине валчыклап бетерү; *раскрошить табак* — тәмәкене ваклау (уып, тапап).

**РАСКРОШИ'ТЬСЯ** *сов.* — ваклану, ватылу, валчыклану; ваклапып (валчыкланып) бетү; ватkаланып бетү; *хлеб раскрошился* — ипи валчыкланып беткән; *зуб раскрошился* — теш ватkаланып беткән.

**РАСКРУТИ'ТЬ** *сов.*— сүтү, сүтеп җибәрү (мәсәлән, бөтерелгән, ишкән яки каткан җепне).

**РАСКРУТИ'ТЬСЯ** *сов.*— сүтелү, сүтелеп китү; *верёвка раскрутилась* — бау сүтелде.

**РАСКРУ'ЧИВАТЬ** *несов.*— к. раскрутить.

**РАСКРУ'ЧИВАТЬСЯ** *несов.*— к. раскрутиться.

**РАСКРЫВА'ТЬ** *несов.*— к. раскрыть.

**РАСКРЫВА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. раскрыться; 2. ачылу, ачыла торган булу; 3. *страд.* ачып җибәрелү, ачып куелу.

**РАСКРЫ'ТИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— к. раскрыть 1, 2, 3, 4; *раскрытие преступления* — җинаятьне ачу, җинаятьнең ачылуы.

**РАСКРЫ'ТЫЙ** — ачык, ачылган, ачып куелган; *раскрытая книга* — ачып куелган китап.

**РАСКРЫ'ТЬ** *сов.*— 1. ачу, ачып җибәрү, ачып ташлау, ачып кую; *раскрыть сундук* — сандыкны ачу; 2. җәю, җәеп җибәрү; *раскрыть крылья* — канат(ларны) җәю; 3. *перен.* сөйләп бирү, ачып салу, аңлатып бирү; *раскрыть причину своей радости* — шатлыгының сәбәбен ачып салу; 4. *перен.* ачу, фаш итү; тикшереп белү, ачыклау; *раскрыть преступление* — җинаятьне ачу; 5. (мөмкинлекләр) ачу, тудыру; *новые изобретение раскрыло широкие перспективы для производства* — яңа уйлап табу житештерүне үстерү өчен киң мөмкинлекләр тудырды. ◇ (Широко) раскрыть глаза или рот *перен.*— күзе шар булу, гаҗәпләнү, шаккату. Раскрыть (свои) карты — к. карта. Раскрыть скобки *мат.*— җәяләрне ачу (җәя эчендәге гамәлне эшләп).

**РАСКРЫ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. өстен ачу; *холодно, зачем ты раскрылся?*— салкын бит, нигә син өстеңне ачтың? 2. ачылу, ачылып китү; *дверь раскрылась* — ишек ачылды; 3. беленү, фаш ителү, фаш булу; мәгълүм булу, билгеле булу; *преступление раскрылось* — җинаять фаш ителде; 4. (мөмкинлекләр) ачылу (туу).

**РАСКУДА'ХТАТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. *(о курице)* бик каты кытаклый башлау, кыткылдый башлау, кытаклап җибәрү; 2. *перен. простореч.* *(раскричаться попусту)* урынсызга кычкырына башлау, акырына башлау; юкка җикеренә башлау, шау-шу күтәрү.

**РАСКУЛА'ЧИВАНИЕ** *ср. мн.* нет, *истор.*— к. раскулачить.

**РАСКУЛА'ЧИВАТЬ** *несов.*— к. раскулачить.

**РАСКУЛА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— раскулачить ителү, сыйныф булу ягыннан бетерелү (кулаклар турында).

**РАСКУЛА'ЧИТЬ** *сов. истор.*— раскулачить итү (кулакларны — авыл буржуазиясен сыйныф булу ягыннан бетерү максаты белән, алар кулындагы җир һәм житештерү средстволарын конфискацияләү).

**РАСКУМЕ'КАТЬ** *сов. простореч. фам.*— аңлау, төшенү; аңлап алу, төшенеп алу.

**РАСКУПА'ТЬ** *несов.*— к. раскупить.

**РАСКУПА'ТЬСЯ** I *несов. страд.*— сатылып бетү, алып бетерелү, сатып алып бетерелү.

**РАСКУПА'ТЬСЯ** II *сов. простореч.*— бик озак су коену, бик күп су керү, су керү белән мавыгып китү.

**РАСКУПИ'ТЬ** *сов.*— сатып алып бетерү, берсен дә калдырмый алып бетерү (товарны).

**РАСКУ'ПОРИВАТЬ** *несов.*— к. раскупорить.

**РАСКУ'ПОРИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. раскупориться; 2. *страд.* бөкесе алыну, бөкесе чыгарылу; ачылу.

**РАСКУ'ПОРИТЬ** *сов.*— бөкесен алу, бөкесен чыгару; ачу; *раскупорить бутылку* — шешәнең бөкесен чыгару; *раскупорить ящик* — ящикны ачу.

**РАСКУ'ПОРИТЬСЯ** *сов.*— ачылу, бөкесе чыгу (мәсәлән, шешә бөкесе).

**РАСКУРА'ЖИТЬСЯ** *сов. простореч. фам.*— артык әтәчләнеп китү, артык тәкәбберләнү, кылану.

**РАСКУ'РИВАТЬ** *несов.*— 1. к. раскурить; 2. *простореч. фам.* тәмәке тартып (көйрәтеп, төтәтеп) утыру, тәмәке тартып вакыт үткәрү; *работы по горло, а он раскуривает* — эш муеннан, ә ул тәмәке тартып утыра.

**РАСКУ'РИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. раскуриться; 2. *страд.* яндырып җибәрелү, кабызып җибәрелү (тәмәке турында).

**РАСКУРИ'ТЬ** *сов.*— 1. (тарта-тарта) тәмәкене яндырып җибәрү, көйрәтеп җибәрү; 2. тартып бетерү; *мы раскурили весь табак* — булган бөтен тәмәкене тартып бетердек; 3. *простореч.* *(покурить)* бераз тәмәке тарту, тәмәке тартып алу.

**РАСКУРИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. янып китү, кабынып китү, көйрәп китү (тәмәке турында); 2. *простореч.* бертуктаусыз тарту, тәмәке төтәтү; *ну, раскурились, табачники!* — ну, тәмәкечеләр, бертуктаусыз тартасыз!

**РАСКУ'РКА** *ж. простореч.*— 1. *только ед.* к. раскурить 1; 2 тәмәке кәгазе.

**РАСКУСИ'ТЬ** *сов.*— 1. теш белән вату, тешләп вату (яру); *раскусить кедровый орех* — эрбет чикләвеген тешләп вату; 2. *перен. разг. фам.* *(понять)* аңлау, төшенү, аңлап алу, белеп алу.

**РАСКУ'СЫВАТЬ** *несов.*— к. раскусить.

**РАСКУ'СЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— тешләп ватылу.

**РАСКУ'ТАТЬ** *сов.*— (төргәнне) чишү, ачу, сүтү; чишендерү; чишеп ташлау, ачып ташлау; чишеп алу; *раскутать лицо* — йөзен ачу, битен ачу (мәсәлән, юрганга төргән баланың).

**РАСКУ'ТАТЬСЯ** *сов.*— 1. сүтелү, чишелү, ачылу; ачылып китү, чишелеп китү (төргән, ураган нәрсә турында); 2. үзе чишү, салу; өстен ачу.

**РАСКУТИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. *(увлечься кутежами)* типтерүгә (кәеф-сафага, эчүгә) бирелеп китү; 2. *перен. простореч. шутл. (раскошелиться)* юмартланып китү, күп акча туздыру, акча түгү.

**РАСКУ'ТЫВАТЬ** *несов.*— к. раскутать.

**РАСКУ'ТЫВАТЬСЯ** *несов.*— к. раскутаться.

**РАСКУ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. простореч.*— к. раскутиться.

**РА'СОВЫЙ** — 1. раса...-ы; *расовые отличия* — раса аерымлыклары; 2. расачылык...-ы; *расовая теория* — расачылык теориясе.

**РАСПА'Д** *м. мн.* нет, *книж.*— 1. к. распасться; 2. таркалыш; *распад радиоактивных элементов* — радиоактив элементларның таркалышы; 3. череп таркалу; *распад буржуазной культуры* — буржуаз культураның череп таркалуы.

**РАСПА'ДАТЬСЯ** *сов. простореч.*— еш егылгалый башлау; абына башлау, абына (сөртенә) башлау (атлар турында).

**РАСПАДА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. распасться; 2. бетүгә йөз тоту, җимерелә бару, таркала бару.

**РАСПАДЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— таркалу, таркалыш; *распадение молекулы* — молекуланың таркалуы, таркалышы.

**РАСПА'ДОК** *м. обл.*— тар үзән, сыза,

**РАСПА'ИВАТЬ** *несов.*— к. распаять.

**РАСПА'ИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. распаяться; 2. *страд.* эретеп кубарылу (паять ителгән металл турында).

**РАСПА'ЙКА** *ж. мн.* нет, *спец.*— к. распаять.

**РАСПАКОВА'ТЬ** *сов.*— (төргәнне, бәйләгәнне) сүтү, ачу, чишү; ачып алу, чишеп алу.

**РАСПАКОВА'ТЬСЯ** *сов.*— 1. чишелү, сүтелү, чишелеп (сүтелеп) китү, ачылып китү; *свёрток распаковался* — төргәк чишелеп китте; 2. *разг. фам.* (төргән, бәйләгән әйберләрен, товарларын) чишеп бетерү, ачып бушатып бетерү.

**РАСПАКО'ВЫВАТЬ** *несов.*— к. распаковать.

**РАСПАКО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. распаковаться; 2. *страд.* ачып (сүтеп, чишеп) алыну; ачып бушатып куелу.

**РАСПАЛЁННЫЙ** — 1. кызу, эссе, кайнар; (кояштан) кызган, ут кебек кызган; 2. *перен.* ачудан кызган, ачулы.

**РАСПА'ЛЗЫВАТЬСЯ** *несов. разг.*— к. расползтись.

**РАСПАЛИ'ТЬ** *сов.*— бик каты кыздыру, уттай кыздыру, кайнарлату, эсселәтү (тимерком, һава турында). ◇ **Распалить сердце кому-нибудь** — берәүнең йөрәген яндыру, йөрәгенә ут салу, дәртен кузгату.

**РАСПАЛИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. *разг.* бик нык кызу, ут ай кызу; 2. *перен. книж.* кызып китү, кабынып китү, чәпчеп китү; *распалился и наговорил лишнего* — кызып китте дә, артыгын әйтеп ташлады. ◇ **Распалиться гневом** — ачу килү, ачу кабару. **Распалиться любовью** — мәхәббәт кабыну, гыйшык утында яна-көя башлау.

**РАСПАЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. распалить.

**РАСПАЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. распалиться; 2. *страд.* бик нык кыздырылу.

**РАСПА'Р** *м.*— 1. к. распарить 1, распариться 1; 2. *горн.* распар (домна миченең иң киң урыны).

**РАСПА'РИВАТЬ** *несов.*— к. распарить.

**РАСПА'РИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. распариться; 2. *страд.* парда йомшартылу, парландырылу.

**РАСПА'РИТЬ** *сов.*— 1. пешекләү, парлау, парда тотып пешерү; 2. парда тотып йомшарту, пешелә(т)ү; *ивовый прут нужно распарить, чтобы согнуть обруч* — кыршау бөгү өчен, тал чыбыгын парда тотып пешеләтергә кирәк; 3. *безл. простореч.* тирләү, шабыр тиргә бату, манма су булу; *от скорой езды лошадей распарило* — кызу чабудан атлар шабыр тиргә батты; 4. *перен. простореч. фам.* (мунчада) чабынып йомшарту; *распарить косточки* — чабынып сөякләрне йомшарту.

**РАСПА'РИТЬСЯ** *сов.*— 1. пеше(к)ләнү; парда йомшару, парда пешү; *кожа хорошо распарилась* — күн парда яхшы йомшарган; 2. *разг.* тирләү, шабыр тиргә бату; *от быстрой езды лошади распарились* — кызу барудан атлар шабыр тиргә баттылар; 3. *простореч. фам.* артык озак чабыну, артык парлану (мунчада).

**РАСПА'РКА** *ж. мч.* нет, *спец.*— к. распарить 1; *распарка кожи* — тирене парда йомшарту.

**РАСПА'РЫВАТЬ** *несов.*— к. распороть.

**РАСПА'РЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. распороться 1; 2. *страд.* ертып (сүтеп) җибәрелү.

**РАСПАСО'ВКА** *ж.*— распасовка (карта уенында барлык уендашларның „пас“ әйтеп, уеннан баш тартулары).

**РАСПА'СТЬСЯ** *сов.*— 1. җимерелү, ишелү, ватылу; җимерелеп (ишелеп, авып) төшү; таралып китү; *скала распалась* — кыя җимерелеп төште; 2. *науч.* (состав өлешләргә) таркалу, аерылу, бүленү; *молекула распалась на атомы* — молекула атомнарга таркалды; 3. *перен.* таркалу, таркалып бетү; *хоровой кружок распался* — хор түгәрәге таркалды.

**РАСПАТРО'НИВАТЬ** *несов. простореч. шутл.*— к. распатронить.

**РАСПАТРО'НИТЬ** *сов. простореч. шутл.*— акылга утырту, кирәген бирү, арт сабагын укыту.

**РАСПАХА'ТЬ** *сов.*— сөрү, сукалау; сөреп бетерү, сукалап чыгу; сөреп, сукалап ташлау. ◇ **Распахать новь** — чирәм күтәрү.

**РАСПА'ХИВАТЬ** I *несов.*— к. распахать.

**РАСПА'ХИВАТЬ** II *несов.*— к. распахнуть.

**РАСПА'ХИВАТЬСЯ** I *несов. страд.*— сөрелү, сукалану, сөреп (сукаланып) бетерелү; җирәм күтәрелү.

**РАСПА'ХИВАТЬСЯ** II *несов.*— 1. к. распахнуться; 2. *страд.* киң (киереп, тутырып) ачылу; ачып куелу, ачып җибәрелү.

**РАСПАХНУ'ТЬ** *сов.*— 1. киң итеп ачу, киереп ачып җибәрү, тутырып ачып кую, шар ачу; *распахнуть двери* — ишекләрне ачып кую; 2. (чабуларын) ачып җибәрү, җилбәгәй җибәрү.

**РАСПАХНУ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. ачылып китү, киң ачылу; *дверь распахнулась* — ишек ачылып китте; 2. *разг.* җилбәгәй җибәрү, (кием чабуларын) ачып җибәрү, төймәләрен ычкындыру; *шёл распахнувшись* — (пальтосын) җилбәгәй җибәреп бара иде.

**РАСПА'ШКА** I *ж. мн.* нет — 1. к. распахать; 2. сөрелгән җир.

**РАСПА'ШКА** II *ж.*: **на распашку (ходить)** — җилбәгәй (киемне төймәләмичә) йөрү.

**РАСПА'ШНИК** *м. с.-х.* — распашник, яргыч, ике якка өеп сөргеч (сызма культураларның рәт араларын сөрү өчен кулланыла торган махсус сабан).

**РАСПАШНО'Й** I *обл.* — сөрү...-ы; сөрүле, сөрелә торган, сөрергә яраклы; *распашные земли* — сөрелә торган җирләр.

**РАСПАШНО'Й** II — 1. *устар.* җилбәгәй..., төймәләнмичә (каптырмыйча) киелә торган; *распашная шуба* — төймәләмичә киелә торган тун; 2. *спец.* ике якка ачылмалы, ике якка ачыла торган; *распашные двери* — ике якка ачыла торган ишекләр.

**РАСПАШНО'Й** III *спорт.*: **распашное весло** — ике калаклы ишкәк (ике башы белән дә ишеп була торган ишкәк); **распашная лодка** — бер ишкәкле көймә (бер ишкәкнең ике башы белән дә ишеп йөреп була торган көймә).

**РАСПАШО'НКА** *ж. разг.* — бала күлмәге, распашонка (имчәк балаларына кидерә торган, алды яки арты буйдан-буйга ачылмалы күлмәк).

**РАСПАЯ'ТЬ** *сов.* — (эретеп ябыштырылганны) эретеп төшерү, эретеп аеру, эретеп куптару.

**РАСПАЯ'ТЬСЯ** *сов.* — (паять иткән әйбер) эрү, эреп кубып төшү, эреп чыгу.

**РАСПЕ'В** *м.* — 1. к. распеть, распеться 2; 2. *муз.* җыр, җыру; җырлау рәвеше, көй (борынгы чиркәү җыры турында); *древний распев* — борынгы көй. ◇ **На распев** — к. нараспев.

**РАСПЕВА'ТЬ** *несов.* — 1. к. распеть 2; 2. җырлау, көйләү, сузып-сузып җырлау; *работать, распевая песни* — җырлый-җырлый эшләү; 3. *разг.* җырлап вакыт үткәрү, җырлап (җыр сузып) утыру, җырлап йөрү; *целый день распевает, ничего не делает* — көне буе берни эшләмичә җырлап йөри.

**РАСПЕВА'ТЬСЯ** *несов. разг.* — к. распеться.

**РАСПЕКА'НЦИЯ** *ж. разг. устар. шутл.* — каты шелтә, каты кисәтү.

**РАСПЕКА'ТЕЛЬСКИЙ** *разг. фам.* — шелтәләү...-ы; каты кисәтү...-ы; *распекательский тон* — шелтәләү тоны, каты кисәтү тавышы.

**РАСПЕКА'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет, *разг. фам.* — 1. к. распечь; 2. каты шелтә, каты кисәтү.

**РАСПЕКА'ТЬ** *несов. разг. фам.* — к. распечь.

**РАСПЕКА'ТЬСЯ** *несов. страд. разг. фам.* — шелтә бирелү, кызлырылу, пешерелү, сүгелү.

**РАСПЕЛЕНА'ТЬ** *сов.* — биләүне чишү, биләвен сүтеп алу.

**РАСПЕЛЕНА'ТЬСЯ** *сов.* — (үзенең) биләвен чишү, биләве чишелеп (сүтелеп) китү.

**РАСПЕЛЁНЫВАТЬ** *несов.* — к. распеленать.

**РАСПЕЛЁНЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. распеленаться.

**РАСПЕРЕ'ТЬ** *сов.* — 1. (эчтән этеп) яру, вату, ярып җибәрү; (көч белән ике якка) аерып җибәрү; *льдом распёрло замёрзшую бочку* — эчендәге суы туңып, мичкәне ярып җибәргән; 2. *перен. разг. фам.* эшләр тыгызлану, киеренкеләнү; килеп тәрәлү, өелү (эш); 3. *безл. просторечь. пренебр.* симерүдән бүселү, юанаю, тиресенә сыймый башлау.

**РАСПЕТУШИ'ТЬСЯ** *сов. просторечь.* — этәчләнеп китү, туктаусыз кычкырыну (җикеренү); кызып китү, кукраеп китү.

**РАСПЕ'ТЬ** *сов. муз. арго* — 1. җырлап карау, җырлап чыгу; җырны тавышларга салып җырлап чыгу (репетициядә); *распеть хором песню* — җырны хор белән җырлап чыгу; 2. (җырлап) тавышын ачу, тавышын яхшырту; *распеть голос* — җырлый-җырлый тавышын яхшырту.

**РАСПЕ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. дәртләнеп җырлый башлау, җырлый-җырлый кызып китү; җырга бирелеп китү; 2. (*о птицах*) сайрый башлау, кычкыра башлау; 3. яхшы җырлый башлау; (җырлый торгач) тавыш ачылып китү.

**РАСПЕЧА'ТАТЬ** *сов.* — 1. печатен алу, печатен (сургучын) вату; *распечатать помещение* — печатьләнгән бинаның печатен алу (тыюны туктату); 2. (*вскрыть*) ачу, ертып ачу; 3. *перен. просторечь. устар.* яманатын сату, данын сату, фаш итү.

**РАСПЕЧА'ТАТЬСЯ** *сов.* — 1. печате кубып ачылу, ачылып китү (хат, пакет турында); 2. к. расклеиться.

**РАСПЕЧА'ТЫВАТЬ** *несов.* — к. распечатать.

**РАСПЕЧА'ТЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. распечататься; 2. *страд.* печате кубарылу, печате алыну (тыюдан туктатылу).

**РАСПЕ'ЧЬ** *сов. разг. фам.* — (каты) шелтә ясау, шелтәләү, кисәтү; сүгү, орышу, әрләү, кыздыру, пешерү.

**РАСПИВА'ТЬ** *несов. разг. фам.* — 1. к. распить; 1. иркенләп (озаклап) эчеп утыру, чөмереп утыру; *сидим и чай распиваем* — иркенләп чәй эчеп утырабыз (чәйләп утырабыз).

**РАСПИВА'ТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — әкренләп (озаклап) эчелү.

**РАСПИ'ВОЧНАЯ** *в знач. сущ. ж. разг. устар.* — эчү йорты, кабак, мәйханә.

**РАСПИ'Л** *м. спец.* — 1. *только ед.* к. распилить; 2. *(способ распиливания)* яру ысулы, яру рәвеше; киселеш; 3. *(место разреза)* киселгән урын, ярылган урын, кисем.

**РАСПИ'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. распилить.

**РАСПИ'ЛИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. распилиться; 2. *страд.* киселү (аркылыга); ярылу (такта).

**РАСПИЛИ'ТЬ** *сов.* — 1. (пычкы белән) кисү, кисеп чыгару, тураклау; *распилить бревно* — бүрәнәне кисеп чыгару; 2. (пычкы белән) буйга кисү, яру, ярып бетерү; *распилить бревно на доски* — бүрәнәне тактага яру.

**РАСПИЛИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *(поперёк)* киселеп чыгу, киселеп бетү; *(вдоль)* ярылу; 2. *простореч. фам.* кызып кисә башлау, кисү белән мавыгып китү (мәсәлән, утын кисү белән).

**РАСПИ'ЛКА, РАСПИЛО'ВКА** *ж. мн.* нет — пычкы белән кисү; такта яру.

**РАСПИЛО'ВОЧНЫЙ** *тех.* — кисү...-ы; такта яру...-ы; *распиловочный цех* — такта яру цехы.

**РАСПИЛО'ВЩИК** *м. спец.* — такта яручы, кисүче эшче (пычкы һ. б. белән кисүче).

**РАСПИНА'ТЬ** *несов.* — к. распять.

**РАСПИНА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *страд.* (аяккуллары) тәрегә киерелеп кадаклану; 2. *разг. фам. (хлопотать, тратить много сил)* мәшәкатьләнү, күп көч салу (түгү), тырышу, азаплану.

**РАСПИРА'ТЬ** *несов.* — к. распереть.

**РАСПИСА'НИЕ** *ср.* — расписание.

**РАСПИСА'ТЬ** *сов.* — 1. язып чыгу, язып кую; (төрле урыннарга) таратып язу; *расписать слова на карточки* — сүзләрне карточкаларга язып чыгу; 2. рәсем ясап (төрле сурәт төшереп) бизәү, буяп чыгу, бизәп чыгу; бизәкләү, нәкышьләү; *расписать потолок* — түшәмне рәсем ясап бизәү; 3. бүлеп язып чыгу, билгеләп язып кую; *расписать места в санатории* — санаторийдагы урыннарны бүлеп язып чыгу; 4. *перен. разг.* арттырып сөйләү, бизәп (тасвирлап) сөйләү; *расписать происшествие* — вакыйганы арттырып сөйләү; 5. *перен. простореч.* көлкегә калдыру, көлке итеп тасвирлау; *погоди, я уж тебя распишу!* — тукта, мин сине көлкегә калдырырмын әле!

**РАСПИСА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. кул кую, имза кую; *расписаться в получении посылки* — посылканы алу турында кул кую; 2. *перен. ирон. (сознаться)* тану, үз өстенә алу, икърар итү; *расписаться в своей беспомощности* — үзеннең көчсез икәнлегенне (берәр нәрсәгә көчең житмәвен) тану; 3. *простореч.* күп язу; (язу белән) мавыгып китү, кызып китү; *вот расписался, пятое письмо пишет* — менә кызып китте, бишенче хат яза; 4. *простореч.* язылышу (загста никахны рәсмиләштерү).

**РАСПИ'СКА** *ж.* — 1. *только ед.* к. расписать 1, 2, 3; *расписка стен* — стеналарны рәсем ясап бизәү; *расписка счетов* — счётларны таратып язу (теркәп язу); 2. расписка, култамга (билгеле бер нәрсә алуны таныклый торган, алучының кулы куелган документ). ◇ **Под расписку** — кул куйдырып.

**РАСПИСНО'Й** *разг.* — матурлап буялган, рәсемнәр төшерелгән; буяулы, рәсемле, сурәтле, бизәкле, нәкышьле; *расписные стены* — рәсемле стеналар (матур рәсемнәр төшерелгән стеналар); *расписные дуги* — буяулы дугалар. ◇ **Расписные пряники** — кызыл билле прәннекләр.

**РАСПИ'СЫВАТЬ** *несов.* — к. расписать.

**РАСПИ'СЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. расписаться; 2. *страд* язып куелу, язып чыгылу (таратып); бүлеп (билгеләп) язып куелу; 3. *страд.* (рәсемнәр белән) бизәлү, нәкышьләнү.

**РАСПИ'ТЬ** *сов. разг. фам.* — бергәләп эчеп бетерү.

**РАСПИХА'ТЬ** *сов. простореч.* — 1. (төрле жиргә) тыгу, тыгып бетерү, тыгып кую; *распихать всё по карманам* — барысын да кесәләргә тыгып бетерү; 2. ерып үтү, этеп-төртеп үтү, юл ачу; *распихать толпу* — халыкны ерып үтү.

**РАСПИ'ХИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. распихать.

**РАСПИ'ХИВАТЬСЯ** *несов. страд. простореч.* — (төрле жиргә) тыгып куелу, тыгып (салып) бетерелү.

**РАСПИХНУ'ТЬ** *сов. простореч.* — этептөртеп юл ачу, ерып үтү, ерып юл ачу, этә-төртә үтү.

**РАСПЛА'ВИТЬ** *сов.* — эретү (металл, пыяла һ. б. турында).

**РАСПЛА'ВИТЬСЯ** *сов.* — эрү (металл, пыяла һ. б.)

**РАСПЛАВЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. расплавить.

**РАСПЛАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. расплавиться; 2. *страд.* эретелү.

**РАСПЛА'КАННЫЙ** *простореч.* — елап (шешенеп) беткән, елый-елый хәлдән тайган; бик каты елаган.

**РАСПЛА'КАТЬСЯ** *сов.* — 1. бик каты елау, елый башлау, елап җибәрү; 2. туктаусыз елау, туктала алмый озак елау.

**РАСПЛАНИРОВА'ТЬ** *сов.* — 1. планлаштыру, планлап кую, планга салу; *распланировать свои работы* — үз эшләренне планлаштыру; 2. *спец.* план төзү; *распланировать здание* — бинаның планын төзү; 3. *спец.* тигезләү, турылау, такырлау; чистарту, тазарту; *распланировать площадь* — мәйданны тигезләү.

**РАСПЛАНИРО'ВКА** *ж.* — 1. к. распланировать; 2. планлаштырылу, планлаштырылыш; 3. *спец.* план, план сызымы.

**РАСПЛАНИРО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. распланировать.

**РАСПЛАНИРО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — планлаштырылу, планга салыну, план төзелү.

**РАСПЛАСТА'ТЬ** *сов.* — 1. (катламнарга, телемнәргә) аеру, телү, телеп бетерү, яру; *распластать лыко* — курысны телү; 2. *тех. (расплющить)* яньчү, яньчеп юкарту; җәю; 3. *разг. (положить пластом)* җәеп салу, сузып салу, киң (яссы) ягы белән салу.

◇ **Распластать рыбу** — балыкны яру (эчен яру).

**РАСПЛАСТА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — сузылып яту, җәелеп яту; лап итеп егылу.

**РАСПЛАСТОВА'ТЬ** *сов.* — к. пластовать 2.

**РАСПЛА'СТЫВАТЬ** *несов.* — к. распластать.

**РАСПЛА'СТЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. распластаться; 2. *страд.* (катлау-катлау булып) аерылу, теленү, буйга ярылу.

**РАСПЛА'ТА** *ж. мн.* нет — 1. к. расплатиться 1, 2; 2. *перен. книж.* үч алу, үч кайтару; җәза.

**РАСПЛА'ТИТЬСЯ** *сов.* — 1. исәпләшү, исәпне өзү, исәп-хисапны өзү; түләп бетерү; тулысынча түләү, өзелешү; 2. *перен. разг. (отомстить)* үч алу, үч кайтару, исәпләшү; 3. *перен. книж.* җәза алу, җәзага (җавапка) тартылу, җавап бирү; *ему пришлось расплатиться за все свои преступления* — аңа барлык җинаятьләре өчен җавап бирергә туры килде.

**РАСПЛА'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* — к. расплатиться.

**РАСПЛЕВА'ТЬСЯ** *сов. просторeч.* — 1. төкеренү, төкерек чәчү, төкеренә башлау, (озак) төкеренү; 2. *перен. вульг. (рассориться)* ачуланышу, бозылышу; (тиргәшеп) аерылышу, араны өзү.

**РАСПЛЁВЫВАТЬСЯ** *несов. просторeч.* — к. расплеваться.

**РАСПЛЕСКА'ТЬ** *сов.* — чайпалдырып чәчрәтү; чайкалдырып түгү, чайкалдырып түгеп җибәрү, түгеп бетерү; чәчрәтеп бетерү.

**РАСПЛЕСКА'ТЬСЯ** *сов.* — 1 чайпалып чәчрәү; чәчрәп (түгелеп) китү; чайкалып (чайпалып) түгелү; *вода из ведра расплескалась* — чиләктәге су чайкалып түгелде; 2. *(о море)* айкалу-чайкалу, дулкынлана башлау; 3. *разг. фам.* (мавыгып, кызып) су чәчрәтешү, чупырдашу, су сибешә башлау, су сибешеп китү.

**РАСПЛЁСКИВАТЬ** *несов.* — к. расплескать.

**РАСПЛЁСКИВАТЬСЯ** *несов.* — к. расплескаться.

**РАСПЛЕСНУ'ТЬ** *сов. однокр.* — чайкалдырып түгеп җибәрү, чәчрәтеп түгеп җибәрү.

**РАСПЛЕСТИ'** *сов.* — (үргәнне) сүтү, сүтеп кую, сүтеп җибәрү; сүтеп (таратып, тузгытып) ташлау; *расплести косу* — чәч толымын сүтү.

**РАСПЛЕСТИ'СЬ** *сов.* — сүтелү, таралу, сүтелеп китү; *косы расплелись* — чәч толымнары сүтелде.

**РАСПЛЕТА'ТЬ** *несов.* — к. расплести.

**РАСПЛЕТА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. расплестись; 2. *страд.* сүтеп җибәрелү, сүтеп куелу.

**РАСПЛОДИ'ТЬ** *сов.* — (асрап) үрчетү, үстерү; *расплодить кур* — тавык үрчетү.◇ **Расплодить волокиту** *разг. неодобр.* — кәгазь ыгы-зыгысы арттыру, волокита тудыру.

**РАСПЛОДИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. үрчү, арту, артып китү; 2. *перен. разг. неодобр.* җәелеп китү, артык күбәеп китү.

**РАСПЛОЖА'ТЬ** *несов.* — к. расплодить.

**РАСПЛОЖА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. расплодиться; 2. *страд.* үрчетелү, күбәйтелү, арттырылу, ишәйтелү.

**РАСПЛЫВА'ТЬСЯ** *несов.*— к. расплыться.

**РАСПЛЫ'ВЧАТО** *нареч.* — томанлы итеп, аныксыз.

**РАСПЛЫ'ВЧАТОСТЬ** *ж. мн.* нет — аныксызлык, анык булмау, тоныклык; таркаулык, таркау булу, төгәлсезлек, төгәл булмау, томанлы булу; *расплывчатость формулировки* — формулировканың төгәл булмавы (таркаулыгы).

**РАСПЛЫ'ВЧАТЫЙ** — 1. тоныкт; томанланып торган; *расплывчатые очертания гор* — тауларның томанланып торган сызымталары; 2. (йөз сызыклары) анык булмаган, төссез. ◇ **Расплывчатый стиль** — таркау стиль. **Расплывчатые выражения** — аныксыз әйтелмәләр, төрлечә аңларга мөмкин булган сүзләр. **Расплывчатая формулировка** — төгәл булмаган (томанлы) формулировка. **Расплывчатые требования** — катгый булмаган таләпләр, анык булмаган таләпләр.

**РАСПЛЫ'ВШИЙСЯ** — 1. җәелгән, таралган, җәелеп киткән; эреп аккан; 2. *разг.* артык тулы, симез, май баскан.

**РАСПЛЫ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *(о жидкостях)* төрле якка агып китү; җәелү, җәелеп китү; 2. *разг. (об опухоли)* шешеп җәелү, шешеп таралу; 3. *разг.* җәелү, җәелеп китү, кабарып китү; *хлеб расплылся в печи* — икмәк мичтә җәелеп киткән; 4. *перен. разг. фам. шутл. (потолстеть)* юанаеп китү, калынаеп китү; артык симерү, тазару, май басу; 4. төрле якка йөзеп китү; *утки расплылись по озеру* — үрдәкләр күл буйлап төрле якка йөзеп киттеләр.

**РАСПЛЮ'СНУТЫЙ** — ялпак, җәйпәк, яньчек, яссы, юка; юкартылган, яньчелгән; *расплюснутый нос* — яньчек борын.

**РАСПЛЮ'СНУТЬ** *сов.* — к. расплющить.

**РАСПЛЮ'СНУТЬСЯ** *сов.* — к. расплющиться.

**РАСПЛЮ'ЩИВАТЬ** *несов.* — к. расплющить.

**РАСПЛЮ'ЩИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. расплющиться; 2. *страд.* кысып юкартылу, яньчетелү.

**РАСПЛЮ'ЩИТЬ** *сов.* — 1. (кысып, чүкеп, сугып яки бастырып) җәю, яньчү; җәлпәйтү, юкарту; *расплющить головку гвоздя молотком* — кадак башын чүкеч белән сугып җәю; 2. *(раздавить)* басып изү, сыту, вату.

**РАСПЛЮ'ЩИТЬСЯ** *сов.* — 1. җәелү, яньчелү, җәлпәю (кысудан, сугу-чүкүдән); 2. изелү, сытылу, ватылу.

**РАСПЛЯСА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — кызып бии башлау, бии-бии кызып китү, биюгә бирелеп (мавыгып) китү.

**РАСПОГО'ДИТЬСЯ** *сов. просторeч.* — аязу, аязып китү, һава ачылу (яхшыру).

**РАСПОДОБЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *лингв.* — охшашсызлану, диссимиляция (мәсәлән, „шу-

шы", урынына „тушы", „коридор" урынына „колидор" дип әйтү).

**РАСПОДОБЛЯ'ТЬСЯ** *несов. лингв.* — охшашсызландырылу, охшашсызлану, диссимиляцияләнү.

**РАСПОЗНАВА'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — танып беленә торганлык; диагноз куеп булу, авыруның төрен билгеләп булу.

**РАСПОЗНАВА'ЕМЫЙ** *книж.* — (танып) белеп була торган, белү мөмкин булган; билгеләп (диагноз куеп) була торган; *вполне распознаваемые признаки* — танып белү тулысынча мөмкин булган билгеләр.

**РАСПОЗНАВА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — 1. к. распознавать; 2. *мед.* диагноз кую, авыруның төрен билгеләү.

**РАСПОЗНАВА'ТЬ** *несов. книж.* — к. распознать.

**РАСПОЗНАВА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — беленү, билгеләнү, ачыклану, ачыклану.

**РАСПО'ЗНАННЫЙ** *книж.* — беленгән, билгеләнгән; ачыкланган, ачылган, ачык.

**РАСПОЗНА'ТЬ** *сов. книж.* — 1. тану, белү, билгеләү, аеру, ачыклау, аныклау; аңлап алу, төшенү; *на своём опыте распознать* — үз тәҗрибәсеннән чыгып белү, төшенү (үз җилкәсендә татып белү); 2. сизү, белү; сизеп алу, белеп алу; *распознать чужие намерения* — кешеләрнең ниятләрен сизеп алу.

**РАСПОЛАГА'ТЬ** I *несов. книж.* — 1. кулда булу, бар булу, ия булу; *располагать необходимыми средствами* — кирәкле чаралар кулда булу; 2. (үзе теләгәнчә) эш итә алу, тотарга (файдаланырга) хокуклы булу; *он располагает своим имуществом* — ул үз милке белән үзе теләгәнчә эш итә ала; 3. күңелне үзенә тарту, җәлеп итү; мөлаем булу, ягымлы (сөйкемле) булу; *она располагает к себе* — ул күңелне үзенә җәлеп итә; 4. эшкә унай булу, эшкә тарту; *здесь обстановка располагает к работе* — мондагы шартлар эшкә унай (күңелне эшкә тарталар); 5. *устар.* (*намереваться, предполагать*) ният итү, ниятләү, теләү, уйлау. ◇ **Располагайте мною по вашему усмотрению** — мин сезнең ихтыярыгызда (баш өсте, теләсә нинди эш боера аласыз).

**РАСПОЛАГА'ТЬ** II *несов. книж.* — к. расположить.

**РАСПОЛАГА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. расположиться; 2 *страд.* урнаштырылу, җайлаштырылу, җайлап урнаштырылу. ◇ **Обстоятельства располагаются не в его пользу** (Даль) — шартлар аның өчен унай түгел, аның файдасына түгел.

**РАСПОЛАГА'ЮЩИЙ** — 1. *(обладающий)* булган, ия булган, кулында булган; (*распоряжающийся)* хокукы булган, ихтыярында булган; 2. (*предполагающий)* уйлаган, ниятләгән; 3. ягымлы, сөйкемле, мөлаем; җәлеп итә (үзенә тарта) торган; *располагающая внешность* — мөлаем кыяфәт, үзенә тарта торган кыяфәт. ◇ **Располагающий к работе** — эшкә унай, эшкә тарта торган (шартлар).

**РАСПО'ЛЗАТЬСЯ** *сов. разг.* — (төрле якка) үрмәли-шуыша башлау; (күпләп) йөри башлау.

**РАСПОЛЗА'ТЬСЯ** *несов.* — к. расползтись.

**РАСПОЛЗТИ'СЬ** *сов.* — 1. (төрлесе-төрле якка) таралышу; үрмәләп китү, шуышып китү, таралып китү; 2. *разг.* (*о дороге*) изелеп бетү; җәелеп бетү; бозылып бетү; 3. *перен. разг.* (*об одежде*) тузу, ертылу, сүтелү, сыпылу; тетелеп төшү, ертылып (сыпылып, тузып, череп, сәләмәләнеп) бетү; 4. авып бетү, ишелеп төшү, таралып төшү; *забор совсем расползся* — койма бөтенләй таралып төшкән; 5. *перен. разг.* таркалу, таркалып бетү, җимерелү, эштән чыгу, үз эзеннән чыгу; *хозяйство без надзора расползётся* — хуҗалык күзәтүсез таркалып бетәр.

**РАСПОЛОЖЕ'НИЕ** I *ср. мн.* нет — 1. к. расположить; 2. к. расположиться; 3. *воен.* урнашкан урын, урнаштырылган урын; (гаскәр) торган урын, лагерь; *в местах расположения войск* — гаскәр урнашкан урыннарда; 4. тәртип, төзелеш, торыш, урнаштырылыш; урнаштырылу (урнашу) тәртибе; *расположение слов в предложении* — җөмләдә сүзләрнең урнаштырылышы (тәртибе); 5. *физ.* урнашу, ятыш. ◇ **Расположение многочлена** *мат.* — күпбуынны тезү.

**РАСПОЛОЖЕ'НИЕ** II *ср. мн.* нет — 1. яхшы мөнәсәбәт, илтифат; *заслужить чьё-н. расположение* — берәр кешенең илтифатын казану; 2. *перен.* (*симпатия*) ягымлы караш, сөйкемле караш; 3. кәеф, теләк, күңел яту, күңел тарту; *у меня нет расположения играть* — уйнарга теләгем юк; 4. *(наклонность к болезням и т. п.)* бирешүчәнлек, тиз ияртүчән (йоктыручан) булу.

**РАСПОЛО'ЖЕННЫЙ** — урнашкан, җайлашкан; урнаштырылган, җайлаштырылган; утырган, яткан, куелган; *дом был расположен у самой реки* — йорт елганың нәкъ яр буенда (урнашкан) иде; 2. ...-дагы; ...-гы; *расположенный напротив* — каршыдагы; *расположенный на той стороне* — аръяктагы. ◇ **Расположенный многочлен** *мат.* — тезелгән күпбуын.

**РАСПОЛО'ЖЕННЫЙ** II *книж.* — 1. ихлас күңелле, илтифатлы; ягымлы, сөйкемле; 2. теләге булган, күңеле яткан; *я не расположен теперь к серьёзным разговорам* — житди сүзләр сөйләшергә минем хәзер теләгем юк; 3. тиз бирелүчән, бирешүчән (мәсәлән, авыруга).

**РАСПОЛОЖИ'ТЬ** *сов.* — 1. урнаштыру, урнаштырып кую (чыгу); җайлап урнаштыру; тезеп кую, тезеп чыгу; *расположить книги на полках* — китапларны киштәгә тезеп кую; 2. *воен.* (таратып) урнаштыру, кую; *расположить полк на отдых в городе* — полкны ял итү өчен шәһәргә урнаштыру; 3. бүлү, бүлеп чыгу; планлаштыру; (һәрберсен) үз урынына кую; *удачно расположить свои занятия* — эш вакытларын уңай бүлү (планлаштыру); 4. үзенә карату, тарту, җәлеп итү; симпатия кузга-

ту; яхшы караш, яхшы мөнәсәбәт тудыру; *чем ты расположила его к себе?* — нәрсә белән син аны үзенә караттың?

**РАСПОЛОЖИ'ТЬСЯ** I *сов.*— 1. урнашу, урын алу; урнашып алу, җайлашу; *город расположился на реке* — шәһәр елга буена урнашкан (утырган); 2. утыру, утырышу, утырып бетү; яту; *он расположился в экипаже* — ул экипажга утырды; *он расположился спать на диване* — ул йокларга диванга ятты.

**РАСПОЛОЖИ'ТЬСЯ** II *сов. устар. разг.*— уйлау, ниятләү, ният итү, җыену; исәп тоту, күңел утырту; ...-макчы булу, ...-ырга булу; *я уже расположился было ехать на дачу* — мин инде дачага китмәкче булган идем (ниятләгән идем).

**РАСПОЛОСКА'ТЬСЯ** *сов. простореч. разг.*— 1. бик озак (кер) чайкау, чайкау белән мавыгып китү; 2. суда чупырдашу, чупырдашу белән мавыгу; *утки располоскались в луже и не заметили ястреба* — үрдәкләр пычрак суда чупырдаша-чупырдаша карчыга килеп чыкканны сизми дә калдылар.

**РАСПОЛОСОВА'ТЬ** *сов. разг. неодобр.*— (буй-буй итеп) кисү, телү, телгәләү, телеп чыгу, кискәләп ташлау; *располосовать кожу* — күнне буй-буй итеп кисү, телгәләү.

**РАСПОЛОСО'ВЫВАТЬ** *несов. разг. неодобр.*— к. располосовать.

**РАСПО'П** *м. старин.*— урынынннан төшерелгән поп.

**РАСПО'Р** *м. тех.*— ян басым, як-якка этәрү көче (техник конструкцияләр һәм корылмаларда — өстән төшкән басым нәтиҗәсендә туа торган, горизонталь юнәлештәге этәрү көче).

**РАСПО'РКА** I *ж. спец.*— 1. к. распереть 1; 2. *тех.* терәк, терәгеч, терәү, арата.

**РАСПО'РКА** II *ж. мн.* нет, *порт.*— к. распороть.

**РАСПО'РОТЫЙ** — 1. сүтек, сүтелгән, сүтелеп чыккан; ертык, ертылган; 2. эче ярылган.

**РАСПОРО'ТЬ** *сов.*— 1. сүтү, сүтеп җибәрү, сүтеп кую, сүтеп ташлау; *он распорол своё старое пальто* — ул иске пальтосын сүтеп ташлады; 2. эләктереп ерттыру, ертып җибәрү, умырып (аерып) чыгару; *распороть рукав об гвоздь* — җиңне кадакка эләктереп ерттыру; 3. *разг.* (эчен) яру; *волк распорол брюхо овце* — бүре сарыкның корсагын ярган.

**РАСПОРО'ТЬСЯ** *сов.*— сүтелү, сүтелеп чыгу; сүтелеп (ертылып) китү; чәнчелү, ярылу (мәсәлән, эч).

**РАСПО'РОЧНЫЙ** I *тех.*— терәгеч, терәү (арата) ...-ы; *распорочный брус*— терәү борысы.

**РАСПО'РОЧНЫЙ** II *порт.*— сүтү...-ы; сүтә торган.

**РАСПОРЯДИ'ТЕЛЬ** *м.*, **РАСПОРЯДИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж.*— җаваплы кеше; башлык, җитәкчелек итүче, оештыручы, алып баручы; тәртип саклаучы; *распорядитель на демонстрации* — демонстрациягә җаваплы кеше.

**РАСПОРЯДИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — эшне башкара (идарә итә, оештыра) белү, эшчәнлек, җитәкчелек сәләте.

**РАСПОРЯДИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. җитәкчелек итә белүче, эш итә белүче, яхшы оештыра белүче; *распорядительный начальник* — эш итә белүче башлык; 2. тәпле, эшлекле; *распорядительный человек* — тәпле кеше; 3. *офиц.* башкаручы, эш итүче, идарә итүче; боерык (күрсәтмә) бирүче; *распорядительный орган* — боерык бирүче орган. ◇ **Распорядительное заседание суда** *право* — судның башлангыч оештыру утырышы (берәр хөкем эшен турыдан-туры карарга керешү алдыннан хәзерлек утырышы).

**РАСПОРЯДИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. боеру, кушу; боерык бирү, күрсәтмә бирү; *директор распорядился выдать документы* — директор документларны бирергә кушты; 2. оештыру, кайгырту, эш күрү; *распорядиться работами* — эшләрне оештыру, эшләрне башлап җибәрү турында кайгырту; 3. *(найти применение чему-н.)* эш итү, куллану, файдалану.

**РАСПОРЯ'ДОК** *м.* — тәртип; *правила внутреннего распорядка* — эчке тәртип кагыйдәләре.

**РАСПОРЯЖА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. распорядиться; 2. (эшләрне) алып бару, башкару, идарә итү; 3. (*хозяйничать*) хуҗа булу, баш булу, хуҗалык итү; эш йөртү; *у них в доме всем распоряжается мать* — аларның өендә бөтен нәрсәгә әниләре баш (ул хуҗалык итә); 4. боерык (әмер, фәрман) биреп тору, эш кушып тору; *он больше всего любит распоряжаться, а не работать* — эшләүдән бигрәк, ул әмер биреп торырга ярата. ◇ **Право распоряжаться** — эш итәргә хокукы булу, хакы булу.

**РАСПОРЯЖЕ'НИЕ** *ср.*— 1. *только ед.* к. распорядиться, распоряжаться; 2. боерык; күрсәтмә; карар; кушу; *отдать распоряжение* — боерык бирү; *правительственное распоряжение* — хөкүмәт карары; *по распоряжению председателя* — председатель кушуы буенча. ◇ **В распоряжение** *кого-чего* (отправить)—...кул астына, карамагына (җибәрү). **В распоряжении** *кого-чего* (находиться) — карамагында булу, кул астында булу, җитәкчелеге астында булу. **Имею в своём распоряжении два часа** — ике сәгать вакытым бар. **До особого распоряжения** — махсус күрсәтмә булганга чаклы. **Завещательное распоряжение** *право* — васыять кәгазе (язуы), васыятьнамә. **Выдать в распоряжение властей** (преступников)—(җинаятьчеләрне) власть иясләре кулына тапшыру, тотып бирү.

**РАСПОТЕ'ШИТЬ** *сов. простореч.*— күңелленләндерү, көлдерү; юату; күңелне ачып җибәрү, күңелне күтәреп җибәрү (мәс., берәр кызыклы, көлкеле нәрсә сөйләп).

**РАСПОТЕ'ШИТЬСЯ** *сов. простореч.*— юану, шатлану, көлү; күңел күтәрелеп (ачылып) китү.

**РАСПОЯ'САТЬ** *сов.*— (кеше киемендәге) билбауны чишү, путаны чишү, поясны (ка-

ешны) чишеп алу; кәмәрне (кушакны) чишеп җибәрү, чишеп ташлау.

**РАСПОЯ'САТЬСЯ** *сов.*— **1.** билбавын чишү, путасын чишү; *ямщик распоясался* — ямщик билбавын чиште; **2.** *перен. разг. неодобр.* тәртипсезләнү, йөгәнсезләнеп китү, тотнаксызлану; чиктән тыш котырынып китү; *фашистские агрессоры распоясались*— фашистик агрессорлар чиктән тыш котырынып киттеләр.

**РАСПОЯ'СЫВАТЬ** *несов.* — к. распоясать.

**РАСПОЯ'СЫВАТЬСЯ** *несов.*— **1.** к. распоясаться; **2.** *страд.* билбавы чишелү, чишеп алыну.

**РАСПРА'ВА** *ж.*— **1.** *истор.* хөкем, хөкем карары, хөкем карарын җиренә җиткерү; **2.** җәза, җәзалау, җәза бирү; физик җәберләү, көчләү; үч алу; *кулачная расправа* — йодрык җәзасы (йодрыклау, кыйнау); *кровавая расправа* — канлы үч алу; **3.** *истор.* суд (XVIII—XIX йөзләрдә крестьяннар өчен махсус суд); *волостная расправа*— волость суды. ◇ **У него расправа коротка** — аның хөкеме кыска.

**РАСПРА'ВИТЬ** *сов.*— **1.** турайту; турылау, төзәйтү; *расправить спину* — арканы турайту (язу); **2.** (*сделать ровным и гладким*) тигезләү, шомарту; **3.** җәю, киерү, (киереп) ачу; *расправить руки* — кулларын җәю. ◇ **Расправить крылья** *перен.*— к. крыло.

**РАСПРА'ВИТЬСЯ** I *сов.* — 1. (*выпрямиться, вытянуться*) тураю, төзәю, турылану, язылу, җәелү, җәелеп (язылып) китү; **2.** (*сделаться ровным, гладким*) шомару, тигезләнү, тип-тигез булып калу.

**РАСПРА'ВИТЬСЯ** II *сов.*— җәзалау, җәза бирү; үч алу, хисаплашу, кирәген бирү.

**РАСПРАВЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. расправить.

**РАСПРАВЛЯ'ТЬСЯ** I *несов.*— 1. к. расправиться I; **2.** *страд.* турайтылу, төзәйтелү, тигезләп (турайтып) куелу.

**РАСПРАВЛЯ'ТЬСЯ** II *несов.* — к. расправиться II.

**РАСПРЕДЕЛЕ'НИЕ** *ср.*— **1.** к. распределить; **2.** бүленү, бүленеш; *неудачное распределение часов занятий* — эш сәгатьләренең җайсыз бүленүе; **3.** *тех.* бүлгеч механизм (двигательдә пар яки газ бүлүче җайланма). ◇ **Теория распределения** *экон.*— бүленеш теориясе (җәмгыятьтә җитештерелгән нәрсәләрнең бүленеше турындагы теория).

**РАСПРЕДЕЛИ'ТЕЛЬ** *м.*— **1.** бүлүче, бүлеп бирүче, өләшүче, таратучы; **2.** *тех.* к. распределение 3.

**РАСПРЕДЕЛИ'ТЕЛЬНЫЙ** *офиц.* и *тех.*— өләшү...-ы, тарату...-ы, бүлү...-ы; бүлә торган, бүлгеч, бүлүче, өләшүче, таратучы; *распределительная комиссия* — бүлү комиссиясе. ◇ **Распределительный вал** *тех.*— бүлү валы.

**РАСПРЕДЕЛИ'ТЬ** *сов.*— **1.** (*разделить*) бүлү, өләшү, тарату; бүлеп бирү, бүлеп чыгу, өләшеп чыгу; (*поделить между кем-нибудь*) бүлешү, үзара бүлешү; **2.** (*разместить, назначить*) билгеләү, урнаштыру; *распределить людей по работам* — эшчеләрне эшкә урнаштыру; **3.** *науч.* төрен-төренә аеру, төркемләү, төркемләп кую (чыгу); *распределить собранный материал* — җыелган материалны төркемләп чыгу.

**РАСПРЕДЕЛИ'ТЬСЯ** *сов.*— бүленү, аерылу, бүленеп (аерылып) бетү; таралып урнашып бетү.

**РАСПРЕДЕЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. распределить.

**РАСПРЕДЕЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. распределиться; **2.** *страд.* кисәкләргә (өлешләргә) бүлгәләнү; таратылу, бүлеп бирелү, бүлеп куелу, өләшеп чыгылу; урнаштырылу (эшкә).

**РАСПРОДАВА'ТЬ** *несов.* — к. распродать.

**РАСПРОДАВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— сатылу, сатылып бетү.

**РАСПРОДА'ЖА** *ж. мн.* нет— к. распродать.

**РАСПРОДА'ЖНЫЙ** *торг.*— сатып бетерәсе, сатып бетерү өчен билгеләнгән; *распродажный товар* — сатып бетерү өчен билгеләнгән товар.

**РАСПРОДА'ТЬ** *сов.*— сату, сатып бетерү; *мы всё распродали перед отъездом* — без киткәндә бар нәрсәне сатып бетердек.

**РАСПРОПАГАНДИ'РОВАТЬ** *сов.*— пропагандалап ышандыру, тәмам ышандырып җиткерү.

**РАСПРОСТЕРЕ'ТЬ** *сов. книж.*— **1.** (киң) җәю, ачу, киереп ачу; җәеп җибәрү; *распростереть крылья* — канатларны җәю; **2.** *перен. ритор.* үз йогынтың астына алу, үз тәэсиренне җәелдерү (үткәрү); **3.** *перен.* җиткерү.

**РАСПРОСТЕРЕ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — 1. (кулларны җәеп) яту, егылу, сузылып яту; *распростёрся на ковре* — палас өстенә сузылып ятты; **2.** җәелеп китү, ачылып китү; җәйрәп яту, җәелеп яту; (мәсәлән, киң болын); **3.** *перен. ритор.* җәелү, таралу, үтеп керү; *идеи социализма распростёрлись на весь мир* — социализм идеяләре бөтен дөньяга җәелде.

**РАСПРОСТЁРТЫЙ** *книж.*— 1. киң җәелгән, таралган, сузылган; сузылып киткән, җәйрәп яткан (мәсәлән, кыр, басулар); **2.** җәелеп яткан, сузылып яткан (кулларын җәеп, йөзтүбән яки чалкан яткан). ◇ **С распростёртыми объятиями** (*встретить*)— колач җәеп, дүрт куллап, ачык чырай, белән, бик кунакчыл (каршы алу).

**РАСПРОСТИРА'ТЬ** *несов. книж.*— к. распростереть.

**РАСПРОСТИРА'ТЬСЯ** *несов. книж.*— к. распростереться.

**РАСПРОСТИ'ТЬСЯ** *сов.*— **1.** саубуллашу, хушлашу, саубуллашып (хушлашып) китү; саубуллашып (хәерле юл теләп) калу; *распроститься с друзьями* — дуслар белән саубуллашу; **2.** *перен.* (*расстаться*) аерылу, аерылып (ташлап) китү; **3.** *перен.* ...-сыз калу, бәхилләшү, колак кагу; юкка чыгу;

*распроститься со своими вещами* — әйберләреннән колак кагу.

**РАСПРОСТРАНЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. к. распространить; 2. к. распространиться 1, 2, 3, 4, 5; распространяться; 3. таралыш, җәелеш, таралганлык; *скоростные методы получили широкое распространение* — тизләтелгән методлар (белән эшләү) киң таралыш алды.

**РАСПРОСТРАНЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет — таралганлык, җәелгәнлек; таралган булу, еш очрый торган булу; *распространённость этих видов растений очень велика* — бу төр үсемлекләр бик күп таралган.

**РАСПРОСТРАНЁННЫЙ** — киң таралган, җәелгән; күп (еш) очрый торган, киң кулланыла торган; гадәти, гадәттәге; *распространённая ошибка* — күп очрый торган хата. ◇ **Распространённое предложение** *грам.*— җәенке җөмлә.

**РАСПРОСТРАНИ'ТЕЛЬ** *м.*: **распространитель печати** — матбугат таратучы (сатучы); **распространитель ложных слухов** — ялган хәбәрләр таратып йөрүче.

**РАСПРОСТРАНИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.*— мәгънәсен артык киңәйтеп..., артык җәеп...; *распространительное толкование закона* — законның мәгънәсен артык киңәйтеп аңлату.

**РАСПРОСТРАНИ'ТЕЛЬСКИЙ** *спец.* — тарату...-ы, тарата торган; *распространительский аппарат Книгоцентра* — Книгоцентрның тарату бүлеге.

**РАСПРОСТРАНИ'ТЬ** *сов.* — 1. *книж.* киңәйтү, киңәйтеп җибәрү, зурайту; *распространить свои владения* — үз биләмәләрен киңәйтү; 2. җәелдерү; *распространить своё влияние* — үз тәэсирен җәелдерү; 3. тарату, җәелдерү; *распространить просвещение* — аң-белем тарату; 4. тарату; *распространить слух* — хәбәр тарату; 5. *(о запахе)* аңкыту, ис тарату, ис чыгару; 6. *(о свете)* чәчү, сибү, тарату; 7. *(о статье, речи)* озынга сузу, киңәйтү, артык җәю; 8. *(продать)* халык арасында тарату, сату. ◇ **Распространить предложение** *грам.*— җөмләне җәенкеләндерү (иярчен кисәкләр өстәп).

**РАСПРОСТРАНИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *книж.* киңәю, киңәеп китү, зураю; 2. таралу, җәелү; *идеи социализма распространились по всему миру* — социализм идеяләре бөтен дөньяга таралды; 3. таралу, беленү, мәгълүм булу; *слухи распространились* — хәбәр таралды; 4. киң таралу, үтеп керү, массалашу; *просвещение широко распространилось* — мәгърифәт киң таралды; 5. *(о запахе)* аңку; (ис) таралу, җәелү, тулу; 6. *разг.* *(начать говорить пространно)* озын итеп сөйли башлау, артык җәелеп китү; 7. *шутл. просторeч.* җәелеп (киерелеп) утыру; күп урын алып утыру.

**РАСПРОСТРАНЯ'ТЬ** *несов.*— к. распространить.

**РАСПРОСТРАНЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. распространиться; 2. *разг.* күп сөйләп тору, озын-озак сөйләү; артык сүз куерту, сүзне озакка сузу; *считаю лишним долго распространяться на эту тему* — бу темага озак сөйләп торуның кирәге юк дип саныйм; 3. *страд.* киң пропагандалану, таратылу (мәсәлән, аң-белем, тәҗрибә); 4. *страд.* фаш ителү, таратылу (мәсәлән, хәбәр); 5. *страд.* халыкка таратылу, сатылу.

**РАСПРОЩА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— к. распроститься.

**РАСПРЫ'ГАТЬСЯ** *сов.* — сикерену, артык сикеренә башлау, сикерешә башлау; *дети в саду распрыгались* — бакчада балалар сикерешә башладылар.

**РАСПРЫ'СКАТЬ** *сов. разг.*— бөркү, бөркеп чыгу; бөркеп (сиптереп) бетерү.

**РАСПРЫ'СКИВАТЕЛЬ** *м. спец.*— пульверизатор, сиптергеч.

**РАСПРЫ'СКИВАТЬ** *несов.*— к. распрыскать.

**РА'СПРЯ** *ж. книж.*— ызгыш, орышыш, талаш, кычкырыш, җәнҗал; гауга, низаг, тартыш(у), әрләш(ү), даулашу(лар); *политические распри между буржуазными партиями*—буржуаз партияләр арасындагы политик тартышулар.

**РАСПРЯГА'ТЬ** *несов.*— распрячь.

**РАСПРЯГА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. распрячься; 2. *страд.* ту(г)арып куелу, ту(г)арып җибәрелү.

**РАСПРЯ'ЖКА** *ж. мн.* нет, *разг.*— к. распрячь.

**РАСПРЯМИ'ТЬ** *сов.*— турылау, турайту, тигезләү, төзәйтү, яз(ылдыр)у.

**РАСПРЯМИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. турылану, тигезләнү, төзәю; 2. (иелгәннән соң күтәрелеп) тураю, туры (төз) басу; 3. язылып китү, тураеп китү, җәелеп китү (мәсәлән, яна бөгелгән тугым).

**РАСПРЯМЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. распрямить.

**РАСПРЯМЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. распрямиться; 2. *страд.* турайтылу, төзәйтелү, тигезләнелү.

**РАСПРЯ'ЧЬ** *сов.*— тугару, тугарып җибәрү (мәсәлән, атны); тугарып кую, тугарып калдыру.

**РАСПРЯ'ЧЬСЯ** *сов.*— ат тугарылу, тугарылып китү; арба тугарылып калу; дирбия чишелү, өзелү яки бушау.

**РАСПУБЛИКОВА'ТЬ** *сов. офиц.*— бөтен халыкка белдерү, игълан итү, матбугатта басып чыгару.

**РАСПУБЛИКО'ВЫВАТЬ** *несов. офиц.*— к. распубликовать.

**РАСПУБЛИКО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд. офиц.*— бөтен халыкка белдерелү, игълан ителү, матбугатта чыгарылу.

**РАСПУГА'ТЬ** *сов.* — куркытып тарату, куркытып (очырып) җибәрү, өркетеп тарату; куркытып качырып бетерү.

**РАСПУ'ГИВАТЬ** *несов.* — к. распугать.

**РАСПУ'ГИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — куркытылу, өркетелү; куркытып таратылу, таратып бетерелү; куркытып качырылу.

**РАСПУГНУ'ТЬ** *сов. однокр. разг.* — куркытып алу, өркетү, куркытып җибәрү, куркытып качырып җибәрү.

**РАСПУСКА'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. к. распуститься 1, распускаться; 2. к. распустить 4, 5, 6, 7, 8, 9, 10; 3. *хим.* эрү, эретелү (сыекча эчендә).

**РАСПУСКА'ТЬ** *несов.* — к. распустить.

**РАСПУСКА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. распуститься; 2. *страд* таратылу.

**РАСПУСТИ'ТЬ** *сов.* — 1. тарату, таратып җибәрү, кайтарып җибәрү, таратып бетерү; *распустить учеников на каникулы* — укучыларны каникулга тарату; 2. к. *расформировать*; 3. *перен.* бозу, бозып бетерү; узындыру, азындыру, тәртипсезләндерү, йөгәнсезләндерү; *распустить ребёнка* — баланы (иркәләп) бозу; 4. җәю, язу, ачу, җәеп (ачып) җибәрү; *распустить знамёна* — байракларны җәеп җибәрү; 5. киереп кую, кору; *распустить паруса* — җилкәннәрне киереп кую; 6. бушайту, бушайта (җибәрә) төшү; *распустить пояс* — путаны бушайта төшү; *распустить вожжи* — дилбегәне бушайту (буш тотып, атны үз җаена кую); 7. сүтү, тарату, сүтеп таратып җибәрү; *распустить косу* — толымны сүтеп җибәрү; 8. *(растворить)* эретү (мәсәлән, шикәрне суда); 9. *перен. разг. презрит.* агызу, түгү; *распустить слюни* — селәгәй агызу; 10 (сүз, хәбәр) тарату, чәчү. ◇ **Распустить нюни** — к. нюни. **Распустить листья** — яфрак яру, яфраклану. **Распустить почки** — бөреләнү. **Распустить цветы** — чәчәк ату, чәчәкләнү. **Распустить стебли** — сабак чыгару, сабаклану. **Распустить корни** — тамыр җибәрү, тамыр җәю, тамырлану.

**РАСПУСТИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. (яфрак) яру, ярып җибәрү; ачылу, ачылып китү; *почки распустились* — агачларның бөреләре ачылды; 2. *разг.* бушаю, салыну; бушаеп китү, чишелеп китү; *у тебя распустился пояс, поправь* — поясың бушайган, рәтлә; 3. *разг.* (берәр җебе, күзе) ычкыну, сүтелү, китү, сүтелеп китү; *чулок распустился* — оекның күзе киткән (ягъни җебе ычкынып, сүтелеп киткән); 4. (сүтелеп) таралу, таралып китү, тузгып китү; *косы распустились* — толымнары сүтелеп таралып китте; 5. эреп китү, эреп бетү; *сахар распустился в воде* — суда шикәр эреп бетте; 6. *перен.* бозылу, бозылып бетү, азу, азып китү; *дети распустились без присмотра* — балалар караучысыз бозылып беткәннәр. ◇ **Нервы распустились** — нервлары какшаган.

**РАСПУ'ТАТЬ** *сов.* — 1. чуалганны сүтү, чыяләнгәнне чишү; 2. *перен. (разрешить)* чишү, ачыклау, хәл итү, ачыклык кертү, (чуалган эшнен) очына чыгу; 3. *обл. (снять путы)* тышавын алу, богавын алу; тышавын чишеп җибәрү, тышавын салдырып җибәрү (атның).

**РАСПУ'ТАТЬСЯ** *сов.* — 1. *(о спутанном)* сүтелү, чишелү, рәтләнү (чуалган җеп); 2. *перен. разг. (стать ясным)* ачыклану, ачылу, чишелү, хәл ителү, аныклану (эш, мәсьәлә); 3. *перен. разг. (освободиться от чего-н.)* котылу, бушану; ерынып чыгу; 4. *обл.* тышавы чишелү, тышавы төшү, богавы салыну.

**РАСПУ'ТИЦА** *ж. мн.* нет — юл өзеге, юл өзек чак; ни арба, ни чана вакыт; *весенняя распутица* — язгы юл өзеге.

**РАСПУ'ТНИК** *м.* — азгын (бозык, әхлаксыз) ир кеше; уйнашчы.

**РАСПУ'ТНИЦА** *ж.* — бозык хатын, уйнашчы.

**РАСПУ'ТНИЧАТЬ** *несов.* — азып йөрү, азып-тузып йөрү; уйнаш итү, азгынлыкка бирелү, типтерү.

**РАСПУ'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — бозыклык, азгынлык, әхлаксызлык.

**РАСПУ'ТНЫЙ** — бозык, азгын, әхлаксыз; азгынлыкка (бозыклыкка) бирелгән, юлдан язган, типтереп...; *распутный человек* — бозык кеше; *распутная жизнь* — типтереп яшәү.

**РАСПУ'ТСТВО** *ср. мн.* нет — к. распутность.

**РАСПУ'ТЫВАТЬ** *несов.* — к. распутать.

**РАСПУ'ТЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. распутаться; 2. *страд.* сүтелә (чишелә) бару; 3. *страд.* ачыклана (ачыла) бару, хәл ителеп килү; 4. *страд.* (әкренләп) котыла бару, ерынып чыгып килү; 5. *страд.* тышавы салдырылу, тышавы алынып җибәрелү (ат турында).

**РАСПУ'ТЬЕ** *ср.* — юл чаты, юл аермасы, юл аерылышы. ◇ **На распутье** (или **на распутьи**) *перен.* — ике юл чатында (уйга калу, икеләнеп тору, аптырашта калу).

**РАСПУХА'НИЕ** *ср. мн.* нет — к. распухнуть.

**РАСПУХА'ТЬ** *несов.* — к. распухнуть.

**РАСПУ'ХЛЫЙ** *простореч.* — шешкән, шешенгән, кабарган; күпкән, бүртенгән; *распухлые ноги* — шешенгән аяклар.

**РАСПУ'ХНУТЬ** *сов.* — 1. кабару, шешү, шешенү, бүртү, күбенү, бүртенү; шешеп чыгу, шешеп китү; кабарып (бүртеп) чыгу; *палец распух* — бармак шешеп чыкты; 2. *разг. шутл. (разжиреть)* симереп китү, юанаеп китү; 3. *перен. разг. шутл.* артык зураю, калынаеп китү; *во втором издании книга значительно распухла* — икенче басмасында китап шактый калынаеп киткән.

**РАСПУ'ХШИЙ** — к. распухлый.

**РАСПУ'ЧИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. распучить.

**РАСПУ'ЧИТЬ** *сов. безл. простореч.* — кабару, күб(ен)ү; кабарып (күбенеп) чыгу; бүртү; *живот распучило* — корсагы күбеп чыккан.

**РАСПУШИ'ТЬ** *сов.* — к. пушить 1, 3.

**РАСПУШИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — кабарыну; йоннарын (мамыкларын) кабарту, тырпайту, күпертү; *петух распушился* — әтәч кабарынды.

**РАСПУ'ЩЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. *(недисциплинированность)* тәртипсезлек, тыйнаксызлык, башбаштаклык, тотнаксызлык, узынганлык, азганлык; 2. *(развратность, безнравственность)* әдәпсезлек, әхлаксызлык, азгынлык, бозыклык.

**РАСПУ'ЩЕННЫЙ** — 1. таратылган, кайтарып җибәрелгән; *ученики, распущенные на каникулы* — каникулга таратылган укучылар; 2. тузгыган; *распущенные волосы* — тузгыган чәч; 3. җәеп җибәрелгән; *распущенные знамёна* — җәеп җибәрелгән бай-

раклар; 4. тәртипсез, узынган; *распущенные дети* — тәртипсез балалар; 5. *(развратный)* бозык, азгын, бозылган; әдәпсез, әхлаксыз.

**РАСПЫЛА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. к. разгореться 2; 2. кызару, кызарып китү, алсулану, алсуланып китү, кып-кызыл булу; *щёки распылались* — яңаклары алсуланып китте; 3. *перен.* ярсып (кызып) китү; *распылаться гневом* — ачудан ярсып китү.

**РАСПЫЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — к. распылить, распылиться.

**РАСПЫЛЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— таркаулык, таркалганлык; вакланганлык, сибелгәнлек, чәчелгәнлек; *распылённость сил* — көчләрнең таркаулыгы.

**РАСПЫЛЁННЫЙ** — таркау, тар(к)алган, сибелгән, чәчелгән, бүлгәләнеп беткән; *распылённое хозяйство* — таркау хуҗалык.

**РАСПЫЛИ'ТЕЛЬ** *м. тех.* — бөркегеч.

**РАСПЫЛИ'ТЬ** *сов.* — 1. *(измельчить)* ваклау, тузан итү, тузанга әйләндерү; 2. *тех.* бөркү, бөркеп сиптерү; *распылить нефть* — нефтьне бөркеп сиптерү; 3. *перен.* таркату, таратып бетерү, (бүлгәләп) ваклап бетерү; *распылить силы* — көчләрне таркату.

**РАСПЫЛИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *(измельчиться)* ваклану, тузанга әйләнү; 2. *перен.* тар(к)алу, сибелү, таркалып бетү; сибелеп (вакланып, бүлгәләнеп) бетү; *силы распылились* — көчләр таркалып бетте.

**РАСПЫЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. распылить.

**РАСПЫЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. распылиться; 2. *страд.* тузанга әйләндерелү, таратылу, таркатылу; бөркелү.

**РАСПЯ'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. распялить.

**РАСПЯ'ЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— киергечләнү, киереп (киергечләп) куелу, киергәгә тарттырылу.

**РАСПЯ'ЛИТЬ** *сов.* — киерү, киергечләү; киереп (киергечләп) кую; киереп сузу, киереп зурайту, тарттырып кую.

**РАСПЯ'ТИЕ** *ср. книж. церк.* — 1. *только ед.* к. распять; 2. распятие (кул-аяклары хәеп кадакланган Гайса сурәтле зур тәре).

**РАСПЯ'ТЬ** *сов.* — тәрегә кадаклау, кадаклап кую (аяк-кулларны тарттырып тәрегә кадаклап үтерү — борынгы замандагы бер җәза ысулы).

**РАССА'ДА** *ж. мн.* нет, *с.-х. сад.* — рассада, үренте.

**РАССАДИ'ТЬ** *сов.* —1. *(усадив, разместить)* утырту, урнаштыру, утыртып чыгу, утыртып бетерү; 2. *(посадить отдельно)* аерым утырту, (бер-берсеннән) аерып утырту; 3. *(о растениях)* сирәкләп утырту, күчереп утырту (яшелчә үрентеләрен); 4. *перен. просторе*ч. сугып яру, бәреп вату, чәлпәрәмә итү; *рассадить тарелку* — тәлинкәне бәреп вату; 5. *перен. простореч.* (ялгыш) җәрәхәтләү, яралау, кисү; чабу; кистерү, сыдырту; *топором ногу рассадил* — балта белән (ялгыш) аягыма чаптым.

**РАССА'ДКА** *ж. мн.* нет, *с.-х.* — таратып утырту, күчереп утырту, сирәкләп утырту.

**РАССА'ДНИК** *м.* — 1.*с.-х. сад.* рассадник, питомник; үренте түтәле, үрентелек, рассада түтәле; *рассадник цветов* — чәчәк үрентелеге (чәчәк үрентеләре үстерелә торган махсус түтәл яисә хуҗалык); 2. *перен. книж.* чыганак, учак; *рассадник заразы* — йогыш чыганагы (авыру тарата торган урын). ◇ **Племенной рассадник** *с.-х.* — нәселле хайваннар үрчетү хуҗалыгы.

**РАССА'ДНЫЙ** *с.-х.* — рассада...-ы, күчереп утырту...-ы; *рассадный материал* — күчереп утырту материалы (күчереп утыртыласы үрентеләр).

**РАССАДОСАЖА'ЛКА** *ж. с.-х.* — рассада утырткыч, үренте утырткыч.

**РАССА'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. рассадить.

**РАССА'ЖИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. рассесться 1, 2; 2. *страд.* утыртылу; урнаштырылу, аерып утыртылу; 3. *с.-х.* сирәкләп утыртылу, күчереп утыртылу (үрентеләр).

**РАССА'РИВАТЬ** *несов.* — к. рассорить.

**РАССА'РИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. рассориться.

**РАССА'СЫВАНИЕ** *ср. мн.* нет, *мед.* — суырылу, кайту, бетү; *рассасывание опухоли* — шешнең кайтуы.

**РАССА'СЫВАТЬ** *несов.* — к. рассосать.

**РАССА'СЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. рассосаться.

**РАССВЕ'РЛИВАТЬ** *несов.* — к. рассверлить.

**РАССВЕ'РЛИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. рассверлиться; 2. *страд.* бораулап киңәйтелү, бораулап зурайтылу.

**РАССВЕРЛИ'ТЬ** *сов.* — бораулау, бораулап киңәйтү.

**РАССВЕРЛИ'ТЬСЯ** *сов.* — (бораулаудан) киңәю, зураю.

**РАССВЕСТИ'** *сов. безл.* — таң ату, яктыру, яктыра башлау.

**РАССВЕ'Т** *м. мн.* нет — 1. таң, таң ату; *мы выехали с рассветом* — таң аткач чыгып киттек; 2. *перен. поэт.* башлангыч чор, таң; *на рассвете жизни* — гомереңнең таңында.

**РАССВЕТА'ТЬ** *несов.* — к. рассвести.

**РАССВИРЕПЕ'ЛЫЙ** *разг.* — котырынган, бик нык ачулы, бик ачуы кабарган, бик нык ярсыган.

**РАССВИРЕПЕ'ТЬ** *сов.* — (кинәт) бик нык ярсу, бик каты ачулану, ачу килү (кабару); ачуланып (ярсып, котырып) китү; усаллану, ерткычлану, кансызлану, дулау, котырыну.

**РАССЕ'В** *м. с.-х.* — 1. *только ед.* к. рассевать; 2. *(качество, способ посева)* чәчелеш, чәчелү сыйфаты; 3. *тех.* иләк, иләү машинасы (он, ярма, бөртек иләү өчен).

**РАССЕВА'ЛЬЩИК** *м.*, **РАССЕВА'ЛЬЩИЦА** *ж. спец.*— иләүче, иләп чистартучы, сортларга аеручы (эшче).

**РАССЕВА'ТЬ** *несов. устар.* — к. рассеять 1, 2, 4, 5.

**РАССЕВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — чәчелү, таратып чәчелү (ашлык турында).

**РАССЕ'ВЩИК** *м.*, **РАССЕ'ВЩИЦА** *ж. спец.* — к. рассевальщик, рассевальщица.

**РАССЕДА'ТЬСЯ** *несов.* — к. рассесться 2, 3.

**РАССЕДЛА'ТЬ** *сов.* — ияреи алу, ияреи

салдыру; *расседлать коня* — атның иярен салдыру.

**РАССЕДЛА'ТЬСЯ** *сов.* — иярен салу, ияре салыну (иярен ташлау, ияре төшү, ярдән котылу); *конь расседлался* — ат иярен салган.

**РАССЁДЛЫВАТЬ** *несов.* — к. расседлать.

**РАССЁДЛЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. расседлаться; 2. *страд.* ияре салдырылу, ияре алыну.

**РАССЕ'ИВАНИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — 1. к. рассеивать, рассеиваться; 2. чәчелеш, сибелеш, тар(к)алыш; *рассеивание звуков* — тавышның таралышы. ◇ **Рассеивание снарядов** *воен.* — снарядларның сибелеше (бер орудиедән бер үк прицел белән атылган снарядларның төрле урынга төшүе).

**РАССЕ'ИВАТЬ** *несов.* — к. рассеять 2, 3, 4, 5, 6.

**РАССЕ'ИВАТЬСЯ** *несов.* — к. рассеяться.

**РАССЕКА'ТЬ** *несов.* — к. рассечь.

**РАССЕКА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. рассечься; 2. *страд.* киселү, ярылу; кисеп (телеп) чыгарылу, кыеп төшерелү.

**РАССЕКРЕ'ТИТЬ** *сов. канц.* — 1. секретсызландыру; секретлыгын, (яшеренлеген) бетерү (элек секрет булган берәр нәрсә турында); 2. *разг.* секрет эштән бушату (алу, азат итү); *рассекретить сотрудника* — сотрудникны секрет эштән азат итү.

**РАССЕКРЕ'ЧИВАТЬ** *несов. канц.* — к. рассекретить.

**РАССЕКРЕ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд. канц.* — 1. *(о документе, деле)* секретсызландырылу; яшеренлеге (секретлыгы) бетерелү; 2. *(о человеке)* секрет документлар уку рөхсәте алыну; секрет эштән бушатылу (азат ителү).

**РАССЕЛЕ'НЕЦ** *м.* — күчеп утыручы, күчереп утыртылучы.

**РАССЕЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. к. расселить; 2. к. расселиться; 3. таралыш (халыкның мәгълүм бер территориягә таралып урнашуы).

**РАССЕ'ЛИНА** *ж.* — таудагы (тау токымындагы) тирән ярык, ярылган урын; тар упкын, тарлавык.

**РАССЕЛИ'ТЬ** *сов. простореч.* — 1. таратып утырту, күчереп утырту; 2. *(поселить порознь)* бер-берсеннән аерып урнаштыру, төрле урынга (квартирга) урнаштыру.

**РАССЕЛИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — 1. (төрле урыннарга) таралу, күчеп утыру, таралып утыру; 2. *(поселиться порознь)* аерылып урнашу, бер-берсеннән аерым урнашу.

**РАССЕЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. расселить.

**РАССЕЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. расселиться; 2. *страд.* (төрле урыннарга) күчереп утыртылу, таратып утыртылу; 3. *страд.* төрле урынга урнаштырылу, аерым-аерым урнаштырылу.

**РАССЕРДИ'ТЬ** *сов.* — ачуландыру, ачуландырып җибәрү, ачуын китерү, ачуын кабарту.

**РАССЕРДИ'ТЬСЯ** *сов.* — ачулану, ачуланып китү; ачу килү (чыгу), ачу кабару (кузгалу).

**РАССЕ'РЖЕННЫЙ** — ачулы, ачуланган, ачуы чыккан.

**РАССЕРЧА'ТЬ** *сов. простореч. обл.* — к. рассердиться.

**РАССЕ'СТЬСЯ** *сов.* — 1. (таралышып урыннарына) утыру, утырышу, урын алу, (җайлап) урнашу; 2. *разг. фам. (сесть развалясь)* җәелеп утыру, киңәеп (киерелеп) утыру; 3. утырудан ярылу, басылудан ярылу; убып төшү, ишелү; *стена расселась* — стена утырудан ярылган.

**РАССЕЧЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — к. рассечь.

**РАССЕ'ЧЬ** *сов.* — 1. кисү, чабу; кисеп (чабып) чыгару; кыеп төшерү; икегә яру; *рассечь полено* — утынны урталай кисү (кисеп чыгару); *рассечь тушу* — ит түшкәсен чабу (ягъни чапкалап тиешле кисәкләргә аеру); 2. *перен.* (икегә) бүлү, аеру; *шоссе рассекло лес на две части* — шоссе урманны ике өлешкә аерган; 3. *перен.* ярып үтү, кисеп үтү; *пароход рассек волны* — пароход дулкыннарны ярып үтте.

**РАССЕ'ЧЬСЯ** *сов.* — ярылу, сыпылу (чәч яки җеп турында).

**РАССЕ'ЯНИЕ** *ср. книж.* — 1. *только. ед.* к. рассеять 3, 4, 5; 2. *только. ед.* к. рассеяться 1, 2, 3, 4, 5; 3. *(о свете, энергии и т. д.)* таралыш, чәчелеш; сибелү, таркалу; 4. күңел ачу, хозур (сәйран) кылу; 5. *устар.* к. рассеянность 1.

**РАССЕ'ЯННО** *нареч.* — таркау хәлдә, игътибарсыз гына, күңел бирмичә генә.

**РАССЕ'ЯННОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. таркаулык, хәтерсезлек, хәтер чуалган булу; онытучанлык, игътибарсызлык, дикъкатьсезлек; *рассеянность старика* — картның хәтерсезлеге; 2. таралып утыру, сибелеп (чәчелеп, сирәк) утырганлык; *рассеянность населения* — халыкның сирәк утырганлыгы.

**РАССЕ'ЯННЫЙ** — 1. юкка чыккан, беткән; *рассеянные сомнения* — юкка чыккан шикләнүләр; 2. таралып утырган, сибелеп утырган; таркау (анда-санда, сирәк) урнашкан; *рассеянное население* — бик сибелеп утырган халык; 3. *физ.* төрле якка таралган, сибелгән, чәчелгән; *рассеянная энергия* — төрле якка таралган энергия; 4. тоныкь, көчсез; *окна пропускали слабый, рассеянный свет* — тәрәзәдән зәгыйфь һәм тоныкь кына яктылык төшә иде; 5. хәтере чуалчык, таркау, онытучан; игътибарсыз, дикъкатьсез; *он очень рассеян* — ул бик таркау; 6. *(праздный)* эшсез, буш, гамьсез; *он вёл жизнь самую рассеянную (Пушкин)* — ул бик гамьсез тормыш алып бара иде.

**РАССЕ'ЯТЬ** *сов.* — 1. төрле урынга чәчү, сибү, сибеп чәчү; сибеп чыгу; *рассеять рожь* — төрле урынга арыш чәчү; 2. *перен. книж.* (киң) җәелдерү, таратып урнаштыру; күп оештыру, төзү; *рассеять школы по всей стране* — бөтен илдә мәктәпләрне киң җәелдерү; 3. *физ. (ослабить, распылить)* тарату, чәчү, сибү; көчсезләндерү (тавыш, яктылык, нур, энергия һ. б. ш.

турында); 4. *перен. книж.* куып тарату, туздыру, тар-мар итү; таратып җибәрү; *рассеять отряд неприятеля* — дошман отрядын туздыру; 5. *перен. книж.* юкка чыгару, бетерү; *рассеять подозрения* — шик-шөбһәләрне юкка чыгару; 6. *перен. (отвлечь, развлечь)* оныттыру, күңелен ачу, юату.

**РАССЕ'ЯТЬСЯ** *сов. книж.* — 1. җәелү, таралу, сибелү, таралып урнашу; *школы рассеялись по всей стране* — мәктәпләр бөтен илгә җәелделәр; 2. *физ.* тар(к)алу, чәчелү; таралып көчсезләнү, чәчелеп бетү, таралып бетү; *тепло рассеялось* — жылылык таралып бетте; 3. *перен.* таралу, төрле якка таралып (качып) бетү; *туман рассеялся* — томан таралды; 4. *перен.* таралышып китү, таралышып бетү; *толпа рассеялась* — халык төркеме таралышып бетте; 5. *перен.* таралу, үтеп китү, юкка чыгу, бетү; *слухи рассеялись* — хәбәрләр юкка чыкты; 6. *перен.* онытылу, юану, күңел ачып алу; *рассеяться после занятий* — эштән соң бераз күңел ачып алу.

**РАССИДЕ'ТЬСЯ** *сов. просторец.* — күп утыру, озаклап утыру, дөньясын онытып утыру.

**РАССИ'ЖИВАТЬСЯ** *несов. просторец.* — 1. к. рассидеться; 2. озын-озак утырып тору; *мне некогда рассиживаться* — минем озын-озак утырып торырга вакытым юк.

**РАССИРО'ПИТЬСЯ** *сов. разг. фам. шутл.* — артык нечкәреп китү, сентиментальләнү, төчеләнү, изрәү.

**РАССКА'З** *м.* — 1. хикәя; *рассказы Чехова* — Чехов хикәяләре; 2. сөйләү, әйтү; хикәяләү, хикәя (бәян) итү; *по рассказам очевидцев* — күргән кешеләрнең сөйләвенә карагаңда.

**РАССКАЗА'ТЬ** *сов.* — сөйләү, сөйләп бирү, сөйләп аңлату; хикәя итү, хикәяләү, бәян итү; *рассказать сказку* — әкият сөйләү.

**РАССКА'ЗЧИК** *м.*, **РАССКА'ЗЧИЦА** *ж.* — 1. сөйләүче, хикәя сөйләүче; *рассказчик умолк* — сөйләүче тынды; 2. яхшы сөйләүче, оста сөйләүче, матур итеп сөйләүче; *он был природным рассказчиком* — ул бик оста сөйләүче иде; 3. *лит.* хикәяләүче.

**РАССКА'ЗЫВАНИЕ** *ср. мн.* нет — к. рассказать.

**РАССКА'ЗЫВАТЬ** *несов.* — к. рассказать.

**РАССКА'ЗЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — сөйлән(ел)ү; сөйләп бирелү, сөйләп аңлатылу; хикәя ителү, хикәяләнү, бәян ителү.

**РАССКАКА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. (сикереп) бик каты чабу, чаба башлау; *лошади расскакались — не остановить* — атлар бик каты чабалар — туктатып булмый; 2. (сикертеп) чаптыра башлау; *всадник расскакался* — җайдаклы атын чаптыра башлады; 3. бик сикеренү, артык сикеренеп китү; *что это ты расскакался?* — нәрсә син бик сикеренәсең? 4. сикереп китү, калтырау (мәсәлән, язганда каләм).

**РАССЛАБЕВА'ТЬ** *несов. разг.* — хәлсезләнә бару, зәгыйфьләнә бару, көч бетә бару.

**РАССЛАБЕ'ТЬ** *сов. разг.* — к. расслабнуть.

**РАССЛА'БИТЬ** *сов.* — 1. көчсезләндерү, хәлсезләндерү, зәгыйфьләндерү; көчне бетерү, какшату; *болезнь меня совсем расслабила* — авыру мине тәмам какшатты; 2. бушайту, бушайта төшү, бераз иркенәйтү; *расслабить пояс* — поясны бушайта төшү, поясны бераз иркенәйтү.

**РАССЛАБЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. к. расслабить; 2. көчсезлек, хәлсезлек, зәгыйфьлек, дәртсезлек; (сәламәтлек) какшау, ватылу, көч (хәл) бетү.

**РАССЛА'БЛЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — хәлсезлек, көчсезлек, җегәрсезлек, дәртсезлек.

**РАССЛА'БЛЕННЫЙ** — 1. бушайган, бушаеп калган, иркенәйгән (мәсәлән, билбау, бау һ. б.); 2. какшаган, ватылган, рәте киткән, хәлсезләнгән; көчсез; йомшак, тонык, зәгыйфь; *расслабленный организм* — какшаган организм.

**РАССЛАБЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. расслабить.

**РАССЛАБЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — хәлсезләндерелү, көчсезләндерелү.

**РАССЛА'БНУТЬ** *сов. разг.* —(сәламәтлек) какшау, көчсезләнү, хәлсезләнү, хәлдән таю, изрәп төшү, хәл бетү, әлсерәү; *расслаб после бани* — мунчадан соң хәлем бетте.

**РАССЛА'ВИТЬ** *сов. разг.* — 1. артык мактау, мактап җибәрү, даңлыклау, мәдхия уку, күкләргә күтәреп мактау; 2. (сүз, гайбәт) тарату, сөйләп йөрү, даның чыгару, яман атын сату; бөтен халыкка кычкыру, җар салу, фаш итү; *расславил их ссору всему городу* — аларның ызгышын бөтен шәһәргә таратты.

**РАССЛА'ВИТЬСЯ** *сов. устар.* — таралу (сүз, хәбәр турында); даны чыгу, аты-чабы чыгу.

**РАССЛАВЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. расславить.

**РАССЛАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *устар.* к. расславиться; 2. *страд.* кирәгеннән артык мактану; яман аты сатылу.

**РАССЛА'ИВАТЬ** *несов.* — к. расслоить.

**РАССЛА'ИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. расслоиться; 2. *страд.* кат-кат итеп куелу, катлау-катлау итеп аерылу.

**РАССЛЕ'ДОВАНИЕ** *ср.* — к. расследовать; *официальное расследование* — рәсми тикшерү.

**РАССЛЕ'ДОВАТЬ** *сов.* — 1. *книж.* һәрьяклап тикшерү, һәрьяклап карау, һәрьяклап өйрәнү, төпчену, казыну; *расследовать вопрос* — мәсьәләне һәрьяклап тикшерү (өйрәнү); 2. *офиц.* *право* тикшерү үткәрү; *расследовать преступление* — җинаять буенча тикшерү үткәрү.

**РАССЛОЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — к. расслоить, расслоиться.

**РАССЛОЁННЫЙ** — катламнарга аерылган, катланган, катлап салынган, катлап аерылган, катлап куелган.

**РАССЛОИ'ТЬ** *сов.* — 1. катлау, кат-кат итү; катламнарга бүлү, катлам-катлам итеп аеру; *расслоить тесто* — камырны катлау; 2. *перен. книж.* (сыйнфый) катлауларга аеру, социаль төркемнәргә бүлү; *капитализм расслоил крестьянство* — капитализм

крестьяннарны (сыйнфый) катлауларга аерды.

**РАССЛОИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. катлауларга бүленү, катламнарга аерылу; *слюда расслоилась* — слюда катламнарга аерылды; 2. (сыйнфый) катлаулану, (сыйнфый) катлауларга аерылу; *при капитализме деревня расслоилась* — капитализм чорында авыл (сыйнфый) катлауларга аерылды.

**РАССЛО'ЙКА** *ж.*— 1. *только ед.* к. расслоить; 2. *геол.* катлау, катлам, кат.

**РАССЛУ'ШАТЬ** *сов. простореч.*—(азагына кадәр) тыңлау, тыңлап җиткерү, тыңлап бетерү; яхшылап (колак салып) тыңлау; тыңлап төшенү.

**РАССЛЫ'ШАТЬ** *сов.*— ишетеп җиткерү, яхшылап (ачык) ишетү; *не расслышал его слов* — аның сүзләрен ишетеп җиткермәдем.

**РАССМА'ТРИВАТЬ** *несов.*— 1. карау, күзәтү; карап тору, карый бирү; 2. к. рассмотреть.◇ **Рассматривать как...**—... дип хисаплау, исәпләү; ... дип карау,... дип билгеләү, бәя бирү; *ваше предложение можно рассматривать как вполне реальное* — сезнең тәкъдимегезне тулысынча реаль дип исәпләргә мөмкин.

**РАССМА'ТРИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— каралу, тикшерелү; карап, тикшереп чыгылу; фикер йөртелү, фикер алышыну.

**РАССМЕШИ'ТЬ** *сов.*— көлдерү, көлдереп җибәрү; көлдереп бетерү, көлдереп эчне катыру.

**РАССМЕЯ'ТЬСЯ** *сов.*— көлеп җибәрү, көлә башлау, шаркылдап көлешү.

**РАССМОТРЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— 1. к. рассмотреть; 2. *офиц.* карау, тикшерү, тәфтиш; *передать дело на новое рассмотрение* — эшне яңадан карауга бирү.

**РАССМОТРЕ'ТЬ** *сов.*— 1. карап күрү, күреп алу; карап тану, аеру, (карап) табу; *в темноте с трудом рассмотрели дорогу* — караңгыда юлны көчкә карап таптык; 2. (яхшылап, җентекләп) карау, күзәтү; күздән кичерү, карап узу, карап чыгу; *рассмотреть окрестности в бинокль* — тирә-якны бинокль белән җентекләп күзәтү; 3. *офиц.* карау, тикшерү; *рассмотреть заявление* — гаризаны карау; 4. *книж.* тикшереп чыгу, тикшереп анализ ясау, карап исәпкә алу; *рассмотреть все данные за и против* — барлык уңай һәм каршы дәлилләрне тикшереп анализ ясау.

**РАССНАСТИ'ТЬ** *сов. мор.*— мачта һәм җилкәннәрне сүтеп алу, җиһазларны сүтеп алу, корылмаларны алу (корабльнең барлык корылма һәм җиһазларын сүтеп алу); *расснастить яхту* — яхтаның җиһазларын сүтеп алу.

**РАССНА'СТКА** *ж. мн.* нет, *мор.*— к. расснастить.

**РАССНА'ЩИВАТЬ** *несов. мор.*— к. расснастить.

**РАССНА'ЩИВАТЬСЯ** *несов. страд. мор.*— җилкәннәр-мачталар алыну, җиһазлар сүтеп алыну (җилкәнле корабльнең палубасындагы җиһазлар турында).

**РАССОВА'ТЬ** *сов. разг.*— төрле җиргә тыгу, тыгып кую, төрле җиргә тыгып бетерү, тыккалап бетерү; *рассовать по карманам вещи* — әйберләрне кесәләргә тыккалап бетерү.

**РАССО'ВЫВАТЬ** *несов. разг.*— к. рассовать.

**РАССО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— тыгып куелу, тыккалап бетерелү.

**РАССО'Л** *м.*— 1. *(для засола)* тозлы су, тоз салынган су, тозлык (берәр нәрсә тозлау өчен хәзерләнгән тозлы су); 2. тозлаган ... суы; тозлы ... суы; *огуречный рассол* — тозлаган кыяр суы; 3. тозланыш; тозлану дәрәҗәсе, тозлау сыйфаты; *слабый рассол* — тозланышы начар; 4. *спец.* тоз суы (тоз чыгарыла торган су); 5. *тех.* тоз эремәсе.

**РАССО'ЛЬНИК** I *м. кулин.*— рассольник (тозлаган кыяр салып пешерелгән итле аш яки балык ашы).

**РАССО'ЛЬНИК** II *м. спец.*— тозлы су коесы (тоз чыгара торган урыннарда).

**РАССО'ЛЬНЫЙ** — тозлы, тозла(н)ган.

**РАССО'РИВАТЬ** *несов.*— к. рассорить.

**РАССО'РИВАТЬСЯ** *несов.*— к. рассориться.

**РАССО'РИТЬ** *сов.*— ачуланыштыру; араларын бозу, бозылыштыру; (ачуланыштырып) аеры ыштыру, ташлаштыру.

**РАССОРИ'ТЬ** *сов.*— 1. чүпләү, чүпләп бетерү; чәчеп ташлау, түгеп-чәчеп бетерү, коеп бетерү; *рассорил зерно по двору* — орлыкны ишек алдына түгеп-чәчеп бетергән; 2. *перен. разг. фам.* таратып (туздырып) бетерү; әрәм-шәрәм итү, түгеп (чәчеп) бетерү, исраф итү, җилгә очыру (акчаны).

**РАССО'РИТЬСЯ** *сов.*— ачуланышу, бозылышу; оршышып аерылышу, ташлашу, ара бозылу.

**РАССОРИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— түгелү, чәчелү, коелу; түгелеп-чәчелеп бетү, коелып бетү; *зерно по дороге рассорилось* — орлык юлда коелып беткән.

**РАССОРТИРОВА'ТЬ** *сов. спец.*— сортировка ясау, сортларга аеру, сортларга аерып кую; төрен-төренә аеру.

**РАССОРТИРО'ВКА** *ж. мн.* нет, *спец.*— к. рассортировать.

**РАССОРТИРО'ВЫВАТЬ** *несов. спец.*— к. рассортировать.

**РАССОРТИРО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— сортларга бүленү, сортларга аерылу, сортировкалану; сорты-сортына (төре-төренә) аерып куелу.

**РАССОСА'ТЬ** *сов.*— кайтару, суырту, бетерү; *компрессами рассосать опухоль* — компресслар куеп шешне кайтару.

**РАССОСА'ТЬСЯ** *сов.*— 1. кайту, шиңү, суырылып бетү; *опухоль рассосалась* — шеш кайтты; 2. *перен.* әкренләп бетү; *запасы рассосались* — запаслар әкренләп бетте.

**РАССО'ХА** *ж. обл.*— 1. *(у сохи)* сука башы, сука җәбе; сука станы; 2. *перен.* ике җәпле агач, чатлык (гомумән ике аерылы нәрсә).

**РАССО'ХНУТЬСЯ** *сов.*— коргаксу, кибеп бетү, коргаксып бетү; кибеп ярылу; *бочка*

*рассохлась и не держит воду* — мичкә коргаксыган, суны тотмый.

**РАССО'ШИСТЫЙ** *обл.* — (ике) аерылы, җәпле, чатлы (агач).

**РАССПРА'ШИВАТЬ** *несов.* — 1. к. расспросить; 2. *(спрашивать, выведывая)* төпченү, төпченеп сорашу, сораштыру.

**РАССПРА'ШИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — соралу, сораштырылу, сораулар бирелү.

**РАССПРО'С** *м.* — 1. к. расспросить; 2. *чаще мн.* сораулар, сорашулар, сораштырулар; *при встрече начались расспросы* — күрешкәннән соң сорашулар башланды (очрашу белән сораулар ява башлады).

**РАССПРОСИ'ТЬ** *сов.* — сорашу, сораштыру; сорашып белү, сораштырып белү.

**РАССРЕДОТО'ЧИВАТЬ** *несов. воен.* — к. рассредоточить.

**РАССРЕДОТО'ЧИВАТЬСЯ** *несов. воен.* — 1. к. рассредоточиться; 2. *страд.* таратылу, таратып урнаштырылу.

**РАССРЕДОТО'ЧИТЬ** *сов. воен.* — төрле урынга тарату, таратып урнаштыру.

**РАССРЕДОТО'ЧИТЬСЯ** *сов. воен.* — төрле урынга таралу, җәелү; таралып (сибелеп) урнашу (мәсәлән, гаскәр).

**РАССРО'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. рассрочить.

**РАССРО'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — төрле срокларга бүленү, вакытлар билгеләнелү (мәсәлән, бурыч түләү өчен).

**РАССРО'ЧИТЬ** *сов.* — срокларга бүлү, вакыт билгеләү (бүлеп-бүлеп түләү яки эшне башкару өчен).

**РАССРО'ЧКА** *ж. мн.* нет — рассрочка, өлешләп түләү, ваклап түләү; *приобрёл пальто в рассрочку* — ваклап түләү шарты белән пальто сатып алдым.

**РАССТАВА'НИЕ** *ср.* — к. расстаться.

**РАССТАВА'ТЬСЯ** *несов.* — к. расстаться.

**РАССТА'ВИТЬ** *сов.* — 1. кую, тезү; (үз урынына) куеп чыгу, тезеп чыгу, таратып (урнаштырып) чыгу; урнаштырып кую, тезеп кую; рәтләп кую; *расставить часовых* — часовойлар куеп чыгу; *расставить шахматы* — шахмат фигураларын тезеп кую; 2. салып кую, корып кую; *расставить сети* — тозак корып кую; 3. бүлү, урнаштыру, файдалану; *правильно расставить рабочую силу* — эш көчләрен дөрес урнаштыру; 4. аеру, ачу; аерып кую, аерып басу; *расставить пальцы* — бармакларны аеру; *расставить ножки циркуля* — җәзбәне ачу; 5. *порт.* ялгап (арасына кыстырып) киңәйтү; *расставить спину пиджака* — пинжәкнең аркасын ялгап киңәйтү.

**РАССТА'ВИТЬСЯ** *сов.* — 1. *(поместиться)* урнашу, җайлашу, тезелү; үз урыннарын алу; 2. *(раздвинуться)* аерылу, арасы ачылу; 3. *порт.* киңәю, ялгау куелып киңәю.

**РАССТА'ВКА** *ж. мн.* нет, *порт.* — к. расставить 5.

**РАССТАВЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. расставить.

**РАССТАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. расставиться; 2. *страд.* куелу, тезелү, куеп (тезеп) чыгылу; урнаштырылу, таратып куелу; 3. *страд.* корылу, салыну, корып куелу (ау, тозак һ. б. ш. турында); 4. *страд.* бүленү, бүлеп куелу; бүлеп урнаштырылу, файдаланылу (эш көче һ. б. ш. турында).

**РАССТА'ИВАТЬСЯ** *несов. простореч. фам.* — озак көтеп тору, озын-озак көтеп тору; *нечего расстаиваться, пойдём дальше!* — озак көтеп торуның файдасы юк, әйдә киттек!

**РАССТАНА'ВЛИВАТЬ** *несов.* — к. расстановить.

**РАССТАНА'ВЛИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. расстановиться; 2. *страд.* урнаштырылу, куеп чыгылу, тезелү.

**РАССТАНОВИ'ТЬ** *сов. простореч.* — к. расставить 1.

**РАССТАНОВИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — к. расставиться 1.

**РАССТАНО'ВКА** *ж.* — 1. *только ед.* к. расставить 1, 2, 3, 4; 2. *только ед.* куелыш, бүленеш, урнаштырылыш; бүлеп урнаштырылу, урнаштырылу тәртибе, урнаштыруда эзлеклелек; *расстановка знаков препинания* — тыныш билгеләренең куелышы; 3. *разг.* туктау, тыныш ясау; тукталыш, пауза; *читать с расстановкой* — тыныш ясый-ясый уку; 4. *спорт.* саф, сафка тезелү (гимнастика уеннарында).

**РАССТАНО'ВЩИК** *м. спец.* — тезүче, урнаштыручы, урнаштырып куючы.

**РАССТА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. аерылышу, аерылышып китү; саубуллашып (хушлашып) чыгып китү; *друзья расстались* — дуслар аерылыштылар; 2. аерылу, ташлашу, ташлап китү; *расстаться с семьёй* — семьясыннан аерылу, аерылып китү; 3. *разг. эвф.* саубуллашу, эштән бушату, эштән азат итү; *мы были вынуждены расстаться с этим неисполнительным работником* — безгә ул эш үтәмәс хезмәткәр белән саубуллашырга туры килде; 4. *перен.* ваз кичү, кайту, аерылу, ташлау; *расстался с мыслью о поездке* — юлга чыгу фикереннән кайтты (ваз кичте); *расстался с дурной привычкой* — яман гадәтен ташлады.

**РАССТЕГА'Й** *м.* — 1. *истор. обл.* җилбәгәй сарафан (алдан ачыла торган борынгы сарафан); 2. *кулин.* балык пәрәмәче.

**РАССТЕГА'ТЬ** *сов. порт.* — бизәкләп сыру; *расстегать одеяло* — юрганны бизәкләп сыру.

**РАССТЁГИВАТЬ** I *несов.* — к. расстегнуть.

**РАССТЁГИВАТЬ** II *несов. порт.* — к. расстегать.

**РАССТЁГИВАТЬСЯ** I *несов.* — 1. к. расстегнуться; 2. *страд.* (каптырмасы, төймәсе) ычкындырылу, чишелү; ачып җибәрелү (мәсәлән, күлмәк якасы).

**РАССТЁГИВАТЬСЯ** II *несов. страд. порт.* — сырылу, бизәклә п сырылу.

**РАССТЕГНУ'ТЬ** *сов.* — чишеп җибәрү, төймәне (каптырманы, элмәкне) чишү, ычкындыру; ачып җибәрү; *расстегнуть пальто* — пальто төймәләрен ычкындыру.

**РАССТЕГНУ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. (төймә) ычкыну; чишелеп (ачылып) китү; *у тебя расстегнулась рубашка* — күлмәгеннең

төймәсе ычкынган; 2. *разг.* чишү, төймәсен ычкындыру; җилбәгәй җибәрү, ачып кую; *ходить расстегнувшись* — күкрәген җилбәгәй җибәреп йөрү.

**РАССТЕЛИ'ТЬ** *сов. простореч.* — к. разостлать.

**РАССТЕЛИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — к. разостлаться.

**РАССТИ'Л** *м. мн.* нет, *спец.* — к. разостлать 1.

**РАССТИЛА'ТЬ** *несов.* — к. разостлать.

**РАССТИЛА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. разостлаться; 2. *страд.* җәелү, түшәлү; җәеп куелу, җәеп салыну; 3. таралу; каплап алу, басу, җәелү; *туман расстилается по земле* — җир өстенә томан җәелә; 4. *книж.* җәелеп яту, җәйрәп яту, җәелеп (сузылып) китү; *перед глазами расстилаются необозримые поля* — күз алдында очсыз-кырыйсыз кырлар җәйрәп ята.

**РАССТИ'ЛКА** *ж. мн.* нет, *разг.* — к. разостлать 1.

**РАССТОЯ'НИЕ** *ср.* — 1. ара, ераклык; юл; *кратчайшее расстояние* — иң якын ара; 2. *разг.* ара, дәвам (вакыт турында); *всё произошло на расстоянии двух-трёх часов* — болар барысы ике-өч сәгать арасында (эчендә) булды; 3. *перен.* ара, аерма; *между русской поэзией 18 века и Пушкиным громадное расстояние* — 18 йөз рус поэзиясе белән Пушкин арасында гаять зур аерма бар. ◇ **Держать** *(кого)* **на (известном) расстоянии от себя** — үзенә бик якын җибәрмәү (дуслашырга теләмәү). **Благородное расстояние** — шактый ерак ара.

**РАССТРА'ИВАТЬ** *несов.* — к. расстроить.

**РАССТРА'ИВАТЬСЯ** *несов.* — к. расстроиться.

**РАССТРЕ'Л** *м.* — 1. к. расстрелять; 2. *право* ату (үлем җәзасы); 3. *горн.* терәк, терәү (рудникларны ныгыту өчен).

**РАССТРЕ'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. расстрелять.

**РАССТРЕ'ЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — атылу, атып үтер(т)елү.

**РАССТРЕЛЯ'ТЬ** *сов.* — 1. ату, аттыру, атып үтерү, аттырып үтертү; атып ташлау; *расстрелять шпиона* — шпионны атып үтерү; 2. атып бетерү, атып расходка чыгару; *расстрелять все патроны* — барлык патроннарны атып бетерү; 3. *воен.* (якын дистанциядән) утка тоту; 4. *воен. спец.* күп атып бозу, атып киңәйтү (коралның көпшәсен).

**РАССТРИ'ГА** *м. церк. пренебр.* — расстрига, төшерелгән поп (руханилык дәрәҗәсе алынган поп яки монах).

**РАССТРИГА'ТЬ** *несов.* — к. расстричь.

**РАССТРИГА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. расстричься; 2. *страд.* кыр(к)ылу, киселү, алыну, алдырылу (мәсәлән, чәч); 3. *страд. церк.* руханилыктан төшерелү.

**РАССТРИ'ЧЬ** *сов.* — 1. (кайчы белән) кискәләп бетерү, кыркып бетерү; *расстричь бумагу* — кәгазьне кайчы белән кискәләп бетерү; 2. *церк. устар. (лишить духовного сана)* руханилыктан төшерү.

**РАССТРИ'ЧЬСЯ** *сов.* — руханилык хезмәтен ташлау.

**РАССТРО'ЕННЫЙ** — 1. тәртипсез, туз(дырыл)ган, тар(к)алган; бозылган; *расстроенные ряды противника* — дошманның таркалган сафлары; 2. эздән (чыгырыннан) чыккан, җимерелгән, таркалган, харап булган; *расстроенное хозяйство* — җимерелгән хуҗалык; 3. какшаган,ватылган, рәте киткән, эштән чыккан; *расстроенные нервы* — какшаган нервлар; 4. *муз.* көйсез(ләнгән), көе киткән, бозык; *расстроенный рояль* — бозык рояль; 5. җимерелгән, эшкә (гамәлгә, тормышка) ашмаган, барып чыкмаган; *расстроенный план* — гамәлгә ашмаган план; 6. кайгылы, хәсрәтле, хафалы, кәефсез; сөмсере коелган, кәефе кырылган; *у него расстроенный вид* — аның сөмсере коелган.

**РАССТРО'ИВАТЬ** — к. расстраивать.

**РАССТРО'ИТЬ** *сов.* — 1. туздыру, таркату, таркалыш кертү; туздырып җибәрү (бетерү); *расстроить ряды противника* — дошман сафларын туздыру; 2. җимерү, таркату, харап итү; рәтен җибәрү; эштән (эзеннән, чыгырыннан) чыгару; (эшне) чуалтып бетерү, зарар китерү; *расстроить дела* — эшнең рәтен җибәрү; 3. бозу, какшату, зыян китерү, рәтен китәрү; *расстроить здоровье* — сәламәтлекне какшату; 4. *муз.* көйсезләп (бозып) бетерү; көен бозу, тавышын бозу; *расстроить скрипку* — скрипканың көен бозу; 5. юкка чыгару, тормышка (эшкә) ашыруга комачаулау, җимерү, эшләрен чуалту, бозу; *расстроить замыслы поджигателей войны* — сугыш уты кабызучыларның ниятләрен җимерү; 6. кәефне кыру, кәефен җибәрү; кайгы-хәсрәткә төшерү, хафаландыру; хәтерен (күңелен) калдыру, күңелсезләндерү, борчу; *его ответ расстроил всех* — аның җавабы барысының да кәефен җибәрде.

**РАССТРО'ИТЬСЯ** *сов.* — 1. бозылу, таркалу, таркалып бету, тәртипсез хәлгә килү; *ряды противника расстроились* — дошман сафлары таркалып бетте; 2. рәте китү; эштән чыгу, чыгырыннан чыгу, харап булу, җимерелү, таркалу; зарар килү; *хозяйство расстроилось* — хуҗалык чыгырыннан чыккан; 3. какшау, бозылу, рәте китү; *желудок расстроился* — ашказаны бозылды (эч китә); 4. *муз.* көйсезләнү, көе китү, (көйләгәне) бозылу, тавышы бозылу; *рояль расстроился* — рояль көйсезләнгән; 5. җимерелү, чуалу, сүтелү, рәте китү, эшкә (тормышка) ашмау, барып чыкмау; *план расстроился* — план җимерелде; 6. *разг.* кәеф кырылу, кәеф китү, кәеф бозылу; кайгыру, хафалану, хәсрәткә төшү; борчылу, күңелсезләнү; *он расстроился от неудачи* — уңышсызлыкка очрагач, аның кәефе китте.

**РАССТРО'ЙКА** *ж. мн.* нет, *простореч. устар.* — 1. к. расстроить; 2. к. расстроиться.

**РАССТРО'ЙСТВО** *ср.* — 1. к. расстроить, расстроиться; 2. *только ед.* тәртипсезлек, таркалыш; төзексезлек, рәтсезлек, тузылганлык; *внести расстройство в ряды противника* — дошман сафларына таркалыш

кертү. ◇ **Дела пришли в расстройство** — эшләр тәмам чыгырыннан чыкты. **Нервное расстройство** — нервларның какшаганлыгы. **Он сегодня в расстройстве** — ул бүген бик кәефсез.

**РАССТУПА'ТЬСЯ** *несов.* — к. расступиться.

**РАССТУПИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. ике якка аерылу, аерылып юл ачу, юл бирү, читкә тайпылу; *толпа расступилась* — халык төркеме икегә аерылып юл бирде; 2. *нар.-поэт.* ярылу, аерылу, убылу, убылып төшү; зур ярык хасил булу; *скала расступилась* — кыя ярылды.

**РАССУДИ'ТЕЛЬНО** *нареч.* — уйлап, акыл белән, саклык белән, абайлап; *рассудительно поступить* — уйлап эш итү, абайлап эш итү.

**РАССУДИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. акыллылык, аңлылык; дөрес фикер йөртү, аңлый (төшенә) белү; 2. уйлап (сак, акыл белән) эш итүчелек.

**РАССУДИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. акыллы, аңлы, төпле; уйнап (сак) эш итүчән; *рассудительный человек* — аңлы (төпле) кеше; 2. акылга муафыйк, акылга ятышлы, уйлап (акыл белән) эшләнгән; *рассудительный поступок* — уйлап эшләнгән эш.

**РАССУДИ'ТЬ** *сов.* — 1. (эшне карап, тикшереп, аңлап) хөкем итү, хөкем чыгару; нәтиҗә ясау, карар чыгару, хәл итү, бер фикергә (карарга) килү; *рассудить спор* — бәхәсне хәл итү; *он рассудил, что пришло время приниматься за работу* — ул эшкә керешергә вакыт җитте дигән карарга килде; 2. *(обдумать, сообразить)* ныклап уйлап карау, чамалап (исәпләп) карау; фикер (акыл) йөртеп карау; төбен (асылын) уйлап карау; аңлау, төшенү; *нашим умом этого не рассудишь* — моңа безнең акыл җитәрлек түгел; 3. киңәш бирү, аңлатып бирү; *рассудите, как быть?* — аңлатып бирегезче, ни эшләргә?

**РАССУДИ'ТЬСЯ** *сов. безл. устар.* — тиешле табылу, тиешле күренү, кирәк дип белену.

**РАССУ'ДОК** *м. мн.* нет — 1. *книж.* *(разум)* гакыл, логик фикерләү; *деятельность рассудка* — гакыл эшчәнлеге; 2. акыл, зиһен, аң, баш; төшенүчәнлек, дөрес фикер йөртү; *вопреки рассудку* — акылга каршы буларак.

**РАССУ'ДОЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. абстракт булу, артык гомуми булу (тормыш тәҗрибәсеннән аерылган булу); *рассудочность выводов* — чыгарган нәтиҗәләрнең абстракт булуы; 2. *(о характере)* гакылның хистән өстенлеге, артык коры булу, хиссезлек.

**РАССУ'ДОЧНЫЙ** — 1. гакыл (логик фикерләү)...-ы; *рассудочная деятельность* — гакыл эшчәнлеге; 2. артык гомуми, абстракт; гомуми фикер йөртүләрдән генә торган; фикерләүгә генә нигезләнгән, тормыш тәҗрибәсеннән чыгарылмаган; 3. хистойгысыз, артык коры, гакыл белән генә (эш итүче); *рассудочная любовь* — гакыл белән генә ярату.

**РАССУЖДА'ТЬ** *несов.* — 1. уйлау, фикерләү, фикер (хөкем) йөртү, сүз алып бару; *научиться правильно рассуждать* — дөрес фикер йөртергә өйрәнү; 2. *(обсуждать)* фикер алышу, уртага салып тикшерү; (сүз ачып) фикер йөртү; 3. сөйләү, сөйләнү; әңгәмә кору, сүз куерту, гәп сату; *много рассуждает, да мало делает* — күп сөйли, аз эшли; *рассуждать о всякой всячине* — төрле нәрсәләр турында гәп сату; 4. карулашу, сөйләнү, күп сөйләнеп тору; *не рассуждать!* — күп сөйләнеп тормагыз!

**РАССУЖДЕ'НИЕ** *ср.* — 1. фикер йөртү, хөкем йөртү; фикер, уй; *правильное рассуждение* — дөрес фикер йөртү; 2. карулашу, каршы әйтү, сөйләнү; *исполнять без рассуждений* — кушкан эшне карулашмыйча башкару; 3. *чаще мн.* бәхәсләр, сөйләнүләр; әңгәмә, фәлсәфә; *пускаться в рассуждения* — фәлсәфәгә керешеп китү. ◇ **В рассуждении сего** *канц. устар.* — шул сәбәпле, вә шуңа күрә. **В рассуждении кого-чего** *книж. устар.* —... турысына килгәндә,... ягыннан (җәһәтеннән) карaганда; *кто он такой в рассуждении чина?* — э чин җәһәтеннән караганда кем ул?

**РАССУ'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. рассудить 1.

**РАССУПО'НИВАТЬ** *несов. спец.* — к. рассупонить.

**РАССУПО'НИВАТЬСЯ** *несов. спец.* — к. рассупониться.

**РАССУПО'НИТЬ** *сов. спец.* — чөелдерекне чишү.

**РАССУПО'НИТЬСЯ** *сов. спец.* — чөелдерек чишелү, чишелеп китү.

**РАССУСО'ЛИВАТЬ** *несов. простореч. фам. неодобр.* — озаклап (сузып) сөйләү; артык тәфсилләп сөйләү.

**РАССУ'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. рассучить.

**РАССУ'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. рассучиться; 2. *страд.* сүтелеп ташлану (бау); төшерелү (сызганган җиң).

**РАССУЧИ'ТЬ** *сов.* — 1. сүтү, сүтеп тарату (үргән, ишкән, бөтергән яки катканны); *рассучить верёвку* — бауны сүтү; 2. *разг.* (сызганганны) төшерү; *рассучить рукав* — (сызганган) җиңне төшерү.

**РАССУЧИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. сүтелү, сүтелеп китү (бау); 2. *разг.* төшү (сызганган җиң).

**РАССЧИ'ТАННЫЙ** — 1. исәпләнгән, исәпкә алынган, исәпләп чыгарылган; расчёт ясалган; *неправильно рассчитанный проект* — ялгыш расчёт ясалган проект; 2. алдан исәпләп эшләнгән, ниятләп эшләнгән, юри эшләнгән, усал ният белән эшләнгән; *рассчитанная грубость* — алдан уйлап эшләнгән тупаслык; 3. багышланган, билгеләнгән, ...өчен эшләнгән; *книга, рассчитанная на широкого читателя* — киң катлау укучылар өчен язылган китап; 4. сыйдырышлы, сыешлы,...-лык итеп эшләнгән; *зрительный зал, рассчитанный на 1000 человек* — мең кешелек тамаша залы, мең кеше сыешлы тамаша залы.

**РАССЧИТА'ТЬ** *сов.* — 1. исәпләү, исәпләп чыгару, исәбен белү; *рассчитать стоимость книги* — китапның күпмегә төшкәнен исәпләп чыгару; 2. *тех.* хисаплау, исәп-хисап ясау, техник расчёт ясау, рас-

чётын чыгару; *рассчитать паровой котёл* — пар казанының техник расчётын ясау; 3. исәпкә (искә) алу, чамалап җиткерү, төгәл билгеләү, дөрес бәяләү; *не рассчитал прыжка и попал в лужу* — чамалап җиткермичә сикереп, пычрак суга барып төштем; 4. исәпләп карау; уйлап карау, чамалау, уйлап хәл итү; *рассчитай сам, что лучше* — кайсысы яхшырак икәнен үзең уйлап хәл ит; 5. *(уволить, дать расчёт)* расчёт бирү, (эш хакын түләп) эштән азат итү, эштән чыгару; 6. *воен.* (тәртип буенча) санату, санатып чыгу; *рассчитать взвод* — взводны тәртип буенча санатып чыгу (сафка тезелгәч).

**РАССЧИТА'ТЬСЯ** *сов.*— 1. *(полностью уплатить)* исәпне өзү, исәп-хисапны өзү, исәпләшү; өзелешү, араны өзү; тулысынча түләү, тулы расчёт ясау; 2. *разг. (отомстить, поквитаться)* хисаплашу, үч алу, үч кайтару; 3. *воен.* тәртип буенча санау, санап чыгу; *по порядку номеров рассчитайсь!*— тәртип буенча санагыз (рассчитайсь)!

**РАССЧИ'ТЫВАТЬ** *несов.*— 1. к. рассчитать; 2. өметләнү, өмет итү,... дип исәпләү, чамалау, исәп итү, исәп тоту, күздә тоту; көтү, уйлау; *я не рассчитывал её встретить* — аны очратырмын дип уйламаган идем; 3. өмет тоту, өмет баглау, ышанып тору; ярдәмевә тауну; *я рассчитываю на вас* — мин сезгә өмет баглап торам.

**РАССЧИ'ТЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. рассчитаться; 2. *страд.* исәпләнелү, хисаплап чыгарылу; төгәл расчёт ясалу (*тех.*); 3. *страд.* расчёт бирелү, эштән чыгарылу; 4. җаваплылыгын күтәрү, җавап бирү; җәзасын күтәрү, үз җилкәсендә тату, газабын (җәфасын) күрү; *наделают глупостей, а потом за них рассчитывайся* — ахмаклыклар эшләп ташлыйлар да, аннан соң син алар өчен җавап бир.

**РАССЫЛА'ТЬ** *несов.*— к. разослать.

**РАССЫЛА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— (төрле якка) җибәрелү, таратылу.

**РАССЫ'ЛКА** *ж. мн.* нет — к. разослать.

**РАССЫ'ЛОЧНЫЙ** — җибәрү (тарату)...-ы; җибәрә (тарата) торган; таратыла (җибәрелә) торган; *рассылочный пункт* — тарату пункты.

**РАССЫ'ЛЬНАЯ** *ж.* — курьер хатын, йомышчы хатын.

**РАССЫ'ЛЬНЫЙ** I: **рассыльная книга** — курьер белән җибәрелә торган кәгазьләрне язып бару кенәгәсе.

**РАССЫ'ЛЬНЫЙ** II *в знач. сущ. м.*— 1. курьер, таратучы, йомышка йөрүче (хатлар, кәгазьләр таратып йөри торган кеше); 2. йомышчы малай (революциягә кадәр).

**РАССЫ'П** *м. мн.* нет, *спец. простореч.*— 1. к. рассыпка; 2. к. россыпь 4.

**РАССЫПА'ЛЬЩИК** *м. спец.*, **РАССЫПА'ЛЬЩИЦА** *ж.*— к. рассыпщик.

**РАССЫ'ПАТЬ** *сов.*— 1. түгү, чәчү; чәчеп бетерү, түгеп-чәчеп бетерү, түгеп (чәчеп) җибәрү; *нечаянно рассыпать соль* — тозны ялгыш түгеп җибәрү; 2. сибү; *рассыпать корм* — җим сибү; 3. коюь, коеп бетерү, төшереп җибәрү; *рассыпал карандаши* — карандашларын төшереп җибәрде; 4. (бүлеп) салу, тутыру; *рассыпать муку по мешкам* — онны капчыкларга тутыру; 5. таратып салу, тузгытып ташлау; 6. *перен. воен.* тарату, җәелдерү; таратып (сибеп) урнаштыру; *рассыпать роту в цепь* — ротаны цепькә тарату.

**РАССЫПА'ТЬ** *несов.*— к. рассыпать.

**РАССЫ'ПАТЬСЯ** *сов.*— 1. түгелү, чәчелү, сибелү, коелу; түгелеп китү, түгелеп-чәчелеп бетү; *монеты рассыпались по полу* — вак акча идәнгә коелды; 2. таралу, сибелү; таралышу, таралышып китү; *охотники рассыпались по лесу* — аучылар урманга таралыштылар; 3. *разг.* челпәрәмә килү, вакланып бетү, уалып бетү; *камень рассыпался от взрыва* — шартлаудан таш уалып бетте; 4. *разг.* таркалу, җимерелү; *организация рассыпалась* — оешма таркалды. ◇ **Рассыпаться в комплиментах** — комплимент яудыру. **Рассыпаться в трелях** — чут-чут итеп сайрап җибәрү.

**РАССЫПА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. рассыпаться; 2. *страд.* чәчеп бетерелү.

**РАССЫ'ПКА** *ж. мн.* нет — 1. *разг.* к. рассыпать 1, 2; 2. *торг. (потеря веса в сыпучих товарах)* коелу, кимү, югалу.

**РАССЫПНО'Й** — 1. тарала (чәчелә, сибелә) торган; сибелмәле, чәчелмәле; вак, бөртекле; *рассыпной товар* — вак товар; *рассыпной корм* — бөртекле азык (кошлар һәм балык өчен җим); 2. берәмләп (данәләп) сатыла торган; пачкаланмаган; *рассыпной табак* — пачкаланмаган тәмәке. ◇ **Рассыпным строем** *воен.*— цепькә сибелеп.

**РАССЫ'ПЧАТОСТЬ** *ж. мн.* нет — сибелә (чәчелә) торган булу; таралып (уалып, ярмаланып, бөртекләнеп) тору; таралучанлык, уалучанлык.

**РАССЫ'ПЧАТЫЙ** — сибелүчән, түгелүчән, таралып тора торган, уалып тора торган; бөртекләнеп (ярмаланып) тора торган; ярмалы.

**РАССЫ'ПЩИК** *м. спец.*, **РАССЫ'ПЩИЦА** *ж.*— киптерергә таратучы (эшче).

**РАССЫРО'ПИТЬСЯ** — к. рассиропиться.

**РАССЫХА'ТЬСЯ** *несов.*— к. рассохнуться.

**РАСТАБА'РЫ** *м. простореч. обл.*— юкбар сүзләр, лыгырдау, сафсата.

**РАСТАБА'РЫВАТЬ** *несов. простореч. обл.*— юк-бар сөйләү, ләчтит сату, суган сату, такылдау.

**РАСТА'ИВАТЬ** *несов.*— к. растаять.

**РАСТА'ЛКИВАТЬ** *несов. разг.*— 1. яккякка этү-төртү, этләү-төрткәләү; 2. к. растолкать.

**РАСТА'ЛКИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— төрткәләп уятылу; төрткәләп җибәрелү; (ике якка этеп) ара ачылу, юл бирелү, ерып үтелү.

**РАСТА'ПЛИВАТЬ** *несов.*— к. растопить.

**РАСТА'ПЛИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. растопиться; 2. *страд.* ягып җибәрелү, кабызып җибәрелү; ягып җылытылу; 3. *страд.* (утта) эретелү (май һ. б. ш.).

**РАСТА'ПТЫВАТЬ** *несов.*— к. растоптать.

**РАСТА'ПТЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. *просторен.* к. растоптаться; 2. *страд.* киеп тапталу, киңәйтелү (аяк киеме); 3. *страд.* тапталу, изеп ташлану, басып изелү, аяк астында калу.

**РАСТАСКА'ТЬ** *сов.*— 1. *разг.* (берәм-берәм), ташып бетерү, алып бетерү; 2. *разг.* урлап бетерү, урлап ташып бетерү; 3. сүтеп таратып бетерү, сүтеп ташып бетерү; сүтеп таратып ташлау; *загоревшуюся избу растаскали по брёвнышку* — ут капкан өйнең бүрәнәләрен сүгеп таратып ташладылар.

**РАСТА'СКИВАТЬ** *несов.*— к. растаскать.

**РАСТА'СКИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. (берәм-берәм) алып бетерелү, ташып бетерелү; 2. урлап бетерелү.

**РАСТАСОВА'ТЬ** *сов.*— 1. (уен карталарын) бутау, аралаштыру; 2. *перен. разг. фам. (разместить)* кайсын-кая урнаштыру, таратып урнаштырып бетерү.

**РАСТАСО'ВКА** *ж.*— к. растасовать 1.

**РАСТАСО'ВЫВАТЬ** *несов.*— к. растасовать.

**РАСТАСО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. аралаштырылу, буталтырылу (уен картасы турында); 2. таратып урнаштырылу.

**РАСТА'ЧИВАТЬ** *несов.*— к. расточить 1.

**РАСТА'ЧИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. *тех.* к. расточиться; 2. *страд.* кырып эшкәртелү, кырып ясалу; кырып киңәйтелү, зурайтылу.

**РАСТАЩИ'ТЬ** *сов.*— 1. тартып сузу, тартып киңәйтү, тартып зурайту; *растащить края кожаного мешка* — күн капчыкның кырыйларын тартып киңәйтү; 2. к. растаскать; 3. *разг.* аеру, аерып җибәрү; *растащить дерущихся* — сугышучыларны аерып җибәрү.

**РАСТА'ЯТЬ** *сов.*— 1. эрү, эреп бетү; *снег растаял* — кар эреде; 2. *спец.* эретү, эретеп алу; *растаять лёд* — бозны эретү; 3. *перен. книж.* акрынлап сүнү, тыну, ишетелми башлау; *звуки постепенно растаяли* — тавышлар акрынлап тынды; 4. *перен. книж.* әкренләп бетү, тотылып бетү; *запасы растаяли* — булган запас әкренләп тотылып бетте; 5. күздән югалу, тоныкланып күренмәс булу; *его фигура растаяла вдали* — аның гәүдәсе еракта тоныкланганнан-тоныклана барып күздән югалды; 6. *перен.* күңеле йомша(р)у, эреп китү; *сердце его растаяло от похвалы* — йөрәге мактаудан эреп китте, мактаудан күңеле йомшарды.

**РАСТВО'Р** I *м.*— 1. *разг.* ачылыш, ачылу арасы, ачылу почмагы, ачылу киңлеге; *раствор циркуля* — җәзбәнең ачылу киңлеге; 2. ачык ишек (тәрәзә, капка һ. б.) арасы; 3. *истор.* кечкенә кибет, лавка (иске Россиянең сәүдә рәтләрендә кечкенә кибет).

**РАСТВО'Р** II *м.*— 1. *хим.* эремә; *насыщенный раствор* — туендырылган эремә; 2. *спец. тех.* измә, беришле катнашма; *цементный раствор* — цемент измәсе.

**РАСТВОРЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *спец.*— эрү, эретү; изү, кушу.

**РАСТВО'РЕННЫЙ**— ачык, ачылган; ачып куелган, ачып җибәрелгән, ачык калдырылган; *растворенное окно* — ачык тәрәзә.

**РАСТВОРЁННЫЙ** *спец.*— (сыекчала) эрегән, эретелгән; эремә хәлендәге, сыек хәлендәге.

**РАСТВОРИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет, *науч.* — (сыекчада) эрүчәнлек; эри торган булу, эремә бирү үзлеге.

**РАСТВОРИ'МЫЙ** *науч.*— (сыекчада) эрүчән, эри торган, эретеп була торган.

**РАСТВОРИ'ТЕЛЬ** *м. науч.* — эретүче, эреткеч, эретә торган сыекча; *вода — хороший растворитель* — су — яхшы эреткеч.

**РАСТВОРИ'ТЬ** I *сов.* — 1. ачу, киң итеп (каерып) ачу; тутырып ачып кую, ачып җибәрү, шар ачу; *растворить окна* — тәрәзәләрне ачып җибәрү; 2. *спец.* ачу, җәю, язу; *растворить циркуль* — җәзбәне язу.

**РАСТВОРИ'ТЬ** II *сов.* — 1. (сыекчада) эретү; *растворить сахар в воде* — шикәрне суда эретү; 2. изү, изеп кую; катыштыру, туглау; *растворить хлебы* — ипи изү, камыр кую.

**РАСТВОРИ'ТЬСЯ** I *сов.*— 1. киң ачылу, ачылып китү; *калитка растворилась* — ян капка ачылып китте; 2. *спец.* ачылу, язылу, җәелү (җәзбә, кайчы һ. б. ш. турында).

**РАСТВОРИ'ТЬСЯ** II *сов.*— 1. (сыекчада) эрү, эреп бетү; *сахар растворился в воде* — шикәр суда эрегән; 2. *спец.* изелү, изелеп катышу, аралашу, беришле катнашма булу; 3. *перен. (потеряться среди чего-н.)* эрү, югалу, җиргә сеңгәндәй булу, юкка чыгу, күздән югалу; *он словно растворился* — ул гүя җиргә сеңгәндәй булды.

**РАСТВОРОМЕША'ЛКА** *ж. тех.*— измәболгаткыч (измә хәзерли торган машина).

**РАСТВОРОНАСО'С** *м. тех.*— измә насосы (трубалар аркылы измә кудыра торган насос).

**РАСТВО'РЩИК** *м. спец.*— алтын юучы (химик юл белән алтын юдыртучы эшчебелгеч).

**РАСТВО'РЧАТЫЙ** — ике якка ачылмалы, як-якка ачылмалы.

**РАСТВОРЯ'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *физ.*— к. растворимость.

**РАСТВОРЯ'ЛЬЩИК** *м. спец.* — эремә хәзерләүче (сабын кайнату производствосындагы эшче-белгеч).

**РАСТВОРЯ'ТЬ** I *несов.*— к. растворить I.

**РАСТВОРЯ'ТЬ** II *несов.* — к. растворить II.

**РАСТВОРЯ'ТЬСЯ** I *несов.*— 1. к. раствориться I; 2. *страд.* ачып куелу, ачып җибәрелү, шар ачылу.

**РАСТВОРЯ'ТЬСЯ** II *несов.*— 1. к. раствориться II; 2. *страд.* эретелү, сыеклатылу; изелү, изеп куелу, изеп катыштырылу.

**РАСТЕКА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. растечься; 2. *перен. разг. ирон.* күп (таркау) сөйләү, артык җәелеп сөйләү.

**РАСТЕ'ЛИВАТЬСЯ** *несов. обл. с.-х.*— к. растелиться.

**РАСТЕЛИ'ТЬСЯ** *сов. обл. с.-х.*— бозаулау, бозау китерү.

**РАСТЕ'НИЕ** *ср.*— 1. үсемлек; *культурные растения* — игүле үсемлекләр (игеп үстерелә торган үсемлекләр); *дикие расте-*

*ния* — кыргый үсемлекләр; 2. үлән; *лекарственные растения* — дару үләннәре.

**РАСТЕНИЕВО'Д** *м. спец.* — үсемлекчелек белгече.

**РАСТЕНИЕВО'ДСТВО** *ср. мн.* нет — үсемлекчелек (1. *спец.* үсемлек үстерү, үсемлек үрчетү; 2. *науч.* үсемлекчелек белеме, игүле үсемлекләрне үстерү турындагы фән; *растениеводство разделяется на полеводство, луговодство, огородничество и плодоводство* — үсемлекчелек белеме кырчылык, болынчылык, яшелчәчелек һәм бакчачылык дигән өлешләргә бүленә).

**РАСТЕНИЕВО'ДЧЕСКИЙ** *спец.* — үсемлекчелек...-ы; *растениеводческая специализация* — үсемлекчелек белгечлеге (алу).

**РАСТЕНИЕПИТА'ТЕЛЬ** *м. с.-х.* — үсемлек туклandыргыч (машина).

**РАСТЕПЛИ'ТЬ** *сов. разг.* — күңелне йомшарту, күңелне эретеп җибәрү; *искренность его меня растеплила* — аның эчкерсезлеге минем күңелемне йомшартты.

**РАСТЕРЕБИ'ТЬ** *сов. просторeч.* — 1. тарткалап тузыру, тузгытып бетерү, тараштыру, аралаштыру (чәч-сакалны бармаклар белән); 2. к. расковырять.

**РАСТЕРЕ'БЛИВАТЬ** *несов. просторeч.* — тарткалап утыру; тараштырып (аралаштырып) утыру.

**РАСТЕРЕ'ТЬ** *сов.* — 1. төю, төеп ваклау, уып ваклау, төеп порошок итү, ышкып ваклау; *растереть буру в ступе* — бура ташын килегә салып төю; 2. *(трением размазать)* сөргеп буяп бетерү, ышкып пычратып бетерү, сылап бетерү; 3. ышку, уу; сылау, массаж ясау; *растереть больное место вазелином* — авырткан урынны вазелин белән уу. ◇ **Плюнуть да растереть** *разг. фам. пренебр.* — төкерергә дә тормый. **Растереть в порошок** *перен. разг.* — к. порошок.

**РАСТЕРЕ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. ваклану, уылу, төелү, төелеп бетү; порошокка әйләнү; *покраска хорошо растёрлась* — буяу яхшы вакланды; 2. ышкып корыту, сөртенү; ышкү; *растереться полотенцем после душа* — душтан соң сөлге белән сөртенү.

**РАСТЕРЗА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книжн.* — к. растерзать.

**РАСТЕ'РЗАННЫЙ** — 1. *книжн.* ботарланган, ботарлап (өзгәләп) ташланган; 2. *разг.* ерткаланып беткән, тузган; тетелеп (өзгәләнеп) беткән; *растерзанная книга* — ерткаланып беткән китап; 3. *перен. поэт.* газап чиккән; пара-пара телгәләнгән; *растерзанное сердце* — пара-пара телгәләнгән йөрәк.

**РАСТЕРЗА'ТЬ** *сов.* — 1. *книжн.* ботарлау, ботарлап ташлау, тетеп ташлау, өзгәләп бетерү; телгәләп бетерү; *волки растерзали овцу* — бүреләр сарыкны ботарлап ташлаганнар; 2. *перен. разг.* ерткалап (туздырып) бетерү; *растерзать книгу* — китапны ерткалап бетерү; 3. *перен. поэт.* күңелне әрнетү, газаплау, җәфалау; өзгәләү, изалау, пара-пара телгәләү.

**РАСТЕ'РЗЫВАТЬ** *несов.* — к. растерзать.

**РАСТЕ'РЗЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — ботарлап ташланылу; ерткалап (өзгәләп, телгәләп) бетерелү.

**РАСТЕ'РИВАТЬ** *несов.* — к. растерять.

**РАСТЕ'РИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. растеряться; 2. *страд.* югалтылу, җуелу.

**РАСТЁРТЫЙ** — 1. *(размельченный)* вак, вакланган, төелгән; порошок (он, тузан) кебек булган; 2. сөртелгән, буялган; *грязь, растёртая по всему лицу* — бөтен битенә буялган пычрак; 3. массажланган, массаж ясалган, сыланган, ышкылган, уылган.

**РАСТЕ'РЯ** *м. и ж. просторeч., фам. неодобр.* — к. растеряха.

**РАСТЕ'РЯННОСТЬ** *ж. мн.* нет — каушау, аптырау; каушаганлык, аптыраш, гаҗизлек, чарасызлык; *растерянность во взгляде* — күз карашындагы гаҗизлек.

**РАСТЕ'РЯННЫЙ** — 1. югал(тыл)ган җуелган; *ключи растеряны* — ачкычлар югалган; 2. каушаган, аптыраган, аптырашта (гаҗиз) калган; аптыраулы, каушаулы; *он какой-то растерянный* — ул бик аптыраган (күренә); *растерянный взгляд* — аптыраулы караш.

**РАСТЕРЯ'ТЬ** *сов.* — 1. югалту, җую; югалтып (җуеп) бетерү; *в дороге растерял все вещи* — юлда бар әйберен югалтып бетергән; 2. *перен. (лишиться)* югалтып бетерү; мәхрүм булу; *за годы разлуки растерял всех родных* — читтә яшәү елларында барлык туганнарын югалтып бетергән.

**РАСТЕРЯ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. югалу, җуелу; югалып (җуелып) бетү; төшеп (коелып) калу; түгелеп-чәчелеп бетү; *все вещи растерялись в пути* — юлда бөтен әйберем югалып бетте; 2. каушау, аптырау; югалып (каушап, аптырап) калу; коелып төшү, үзүзеңне югалту, исәңкерәп калу, нишләргә белмәү; *не растеряться перед лицом опасности* — куркыныч алдында аптырап калмаска кирәк.

**РАСТЕРЯ'ХА** *м. и ж. просторeч. фам. неодобр.* — ачык авыз, таркау кеше; онытучан, хәтерсез кеше; әйбер югалтучан (онытып калдыручан) кеше.

**РАСТЕСА'ТЬ** *сов. плотн.* — чабып, (юнып) киңәйтү, зурайтү (агачтагы тишекне).

**РАСТЕСА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *плотн.* юнаюна киңәю, зураю (агач тишеге); 2. *просторeч.* юнышып китү, юну белән мавыгып китү.

**РАСТЁСЫВАТЬ** *несов. плотн.* — к. растесать.

**РАСТЁСЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. растесаться; 2. *страд. плотн.* юнып зурайтылу, юнып киңәйтелү.

**РАСТЕ'ЧЬСЯ** *сов.* — 1. (як-якка) агып китү, җәелү, агып җәелеп китү; *пролитое молоко растеклось по полу* — түгелгән сөт идәнгә җәелде; 2. *перен. разг (об улыбке)* авызы ерылу, авызы җәелү (йөзенә елмаю чыгу).

**РАСТИ'** *несов.* — 1. үсү; буйга җитү, бала чагын үткәрү; *он рос в деревне* — ул авылда үскән, бала чагын авылда үткәргән; 2. *перен.* арту, күбәю; арта (күбәя) бару; *доходы растут* — доходлар артканнан-арта бара; 3. *(увеличиваться в размере)* зураю,

үсү; 4. көчәю, ныгу, кинәю, үскәннән-үсә бару, көч ала бару, киң җәелеш алу; *растёт движение за мир* — тынычлык өчен көрәш көчәя (киң җәелеш ала); 5. *(развиваться)* алгару, алга бару, алга китү, үсү, киң үсеш алу; үскәннән-үсә бару; *растёт промышленность Татарии* — Татарстан промышленносте үсә; 6. камилләшү, үсә (камилләшә) бару; (талант) ачыла бару, җитлегә бару; *писатель растёт с каждым своим произведением* — язучы һәр әсәрендә камилләшә бара; 7. үсү, булу; *пальмы растут в жарких странах* — пальма эссе якларда үсә.

**РАСТИРА'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед.* к. растирать; 2. *мед.* массаж, сылау; *дать растирание* — сыларга кушу.

**РАСТИРА'ТЬ** *несов.* — к. растереть.

**РАСТИРА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. растереться; 2. *страд.* порошокка әйләндерелү; вакландырылу, уылу, төелү; 3. *страд.* ышкылу, сөртелү; массаж ясалу, сыланылу.

**РАСТИ'РКА** *ж. спец.* — 1. *только ед.* к. растереть 1; 2. угыч, төйгеч.

**РАСТИ'РОЧНЫЙ** *спец.* — кыргыч..., кыру...-ы; кыра торган; төю (ваклау)...-ы; *растирочное приспособление* — кыру җайланмасы.

**РАСТИ'РЩИК** *м. спец.* — кыручы, төюче, ваклаучы (эшче); *растирщик красок* — буяу төюче.

**РАСТИ'СКАТЬ** *сов. разг.* — (төрле урынга) тыгызлап тыгып кую, тыккалап бетерү, тыгып чыгу, тыгызлап урнаштыру; *растискал мелкие вещи по корзинам и чемоданам* — вак-төяк нәрсәләрне кәрзиннәргә, чемоданнарга тыккалап бетердем.

**РАСТИ'СКИВАТЬ** I *несов. разг.* — к. растискать.

**РАСТИ'СКИВАТЬ** II *несов. разг.* — к. растиснуть.

**РАСТИ'СКИВАТЬСЯ** I *несов. страд. разг.* — (төрле урынга) тыгызлап тыгылу, тыгып куелу, тыгып бетерелү, тыгызлап урнаштырылу.

**РАСТИ'СКИВАТЬСЯ** II *несов. страд. разг.* — каерып ачылу, киереп ачылу.

**РАСТИ'СНУТЬ** *сов. разг.* — (кыскавны) киереп ачу, каерып ачу; *растиснуть зубы* — тешләрен каерып ачу.

**РАСТИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. *книж.* үсемлекләр; үсемлекләр дөньясы; 2. (тәндәге) йон, төк; *мужчина с пышной растительностью* — йонтәс кеше.

**РАСТИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. үсемлекләр...-ы; *растительный мир* — үсемлекләр дөньясы; 2. үлән...-ы; үләннәрдә була торган, үсемлектә яшәүче; *растительная тля* — үлән бете; 3. үсемлек...-ы; үсемлектән...-гән; *растительные краски* — үсемлекләрдән ясалган буяулар; *растительная пища* — үсемлек ашы; 4. *книж.* үсү...-ы; *растительный процесс* — үсү процессы, үсү барышы. ◇ **Растительная жизнь** *книж. ирон. перен.* — үсемлек тормышы (ягъни рухи интерессыз яшәү). **Растительный орнамент** *искус.* — үсемлек орнаменты, чәчәк орнаменты (үлән-чәчәк рәсемнәренә нигезләнгән бизәкләү-нәкышьләү алымы). **Растительное масло** — үсемлек мае (көнбагыш, киндер, мамык мае һ. б. ш. майларның гомуми атамасы).

**РАСТИ'ТЬ** *несов.* — 1. үстерү, тәрбияләү, карау; тәрбияләп үстерү, карап үстерү, буйга җиткерү; *трудно было вдове растить своих детей* — тол хатынга балаларын тәрбияләп үстерү бик авыр булды; 2. (игеп) үстерү, тәрбияләп үстерү, җитештерү; *растить цветы* — чәчәкләр үстерү; *растить овощи* — яшелчә үстерү; 3. *(о животных)* үрчетү, асрау; карап үстерү, асрап үстерү.

**РАСТЛЕВА'ТЬ** *несов. книж.* — к. растлить.

**РАСТЛЕВА'ТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. к. растлиться; 2. *страд.* көчләнелү, аздырылу.

**РАСТЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — 1. к. растлить, растлиться; 2. *перен.* рухи таркалу, әхлакый таркалу, череп таркалу; әшәкелек, бозыклык; *буржуазное общество дошло до полного растления* — буржуаз җәмгыять тәмам череп таркалуга житте.

**РАСТЛЕ'ННЫЙ** *прич. книж.* — бозык, черек, череп таркалган; *растленная буржуазная идеология* — черек буржуаз идеология.

**РАСТЛИ'ТЬ** *сов. книж.* — 1. (балигъ булмаган кыз баланы) көчләү, гыйффәтен бозу; 2. *перен.* *(нравственно развратить)* юлдан яздыру, аздыру, бозыклыкка кертү; мораль таркату, эштән чыгару.

**РАСТЛИ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — бозылу, бозык юлга керү, азып китү, череп таркалу.

**РАСТОЛКА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. як-якка этәрү, этеп җибәрү; этkәләп-төртkәләп аеру, аерып җибәрү; *растолкать дерущихся* — сугышучыларны аерып җибәрү; 2. этеп-төртеп (аралап) юл ачу, ерып үтү, ерып чыгу; (ике якка) этү, этәреп урын бушату; *растолкал соседей и сел* — күршеләрен этеп-төртеп урын бушатты да утырды; 3. төртkәләп уяту; *кондуктор растолкал спящего* — кондуктор йоклаучыны төртkәләп уятты.

**РАСТОЛКНУ'ТЬ** *сов. разг. фам. однокр.* — этеп кую, төртеп кую, этеп аеру.

**РАСТОЛКОВА'ТЬ** *сов.* — (ачык) аңлату, төшендерү, яхшылап аңлатып бирү, төшендереп бирү; мәгънәсен аңлатып бирү; бәян итү, аңлатма бирү; *растолковать статью закона* — закон статьясының мәгънәсен аңлатып бирү.

**РАСТОЛКОВА'ТЬСЯ** *сов. простореч. фам.* — сүзгә мавыгып китү.

**РАСТОЛКО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. растолковать.

**РАСТОЛКО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. растолковаться; 2. *страд.* аңлатылу, төшендерелү, аңлатма бирелү.

**РАСТОЛО'ЧЬ** *сов.* — төю, төеп ваклау; *растолочь перец* — борыч төю.

**РАСТОЛСТЕ'ТЬ** *сов.* — юанаю, калынаю, юанаеп китү.

**РАСТОПИ'ТЬ** *сов.* — 1. (мичкә) ягу, ягып (кабызып, яндырып) җибәрү; *растопить печь* — мичкә ягып җибәрү; 2. эретү; *растопить воск* — балавыз эретү.

**РАСТОПИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. янып китү,

кабынып (дөрләп) китү; *печь растопилась очень быстро* — мич бик тиз кабынып китте; 2. эрү, эреп китү, эреп бетү; *масло растопилось* — май эреде.

**РАСТО'ПКА** *ж. мн.* нет — 1. к. растопить 1; 2. *собир. разг.* чыра, йомычка; *берёзовая растопка* — каен чырасы.

**РАСТОПЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. растопить.

**РАСТОПЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. растопиться; 2. *страд.* ягып җибәрелү, кабызылу; 3. *страд.* эретелү.

**РАСТО'ПОЧНЫЙ** *разг.* — кабызу...-ы; яндырып җибәрү...-ы; кабызгыч..., чыралык; *растопочные материалы* — кабызу материаллары.

**РАСТОПТА'ТЬ** *сов.* — 1. таптау, таптап китү, таптап бетерү, таптап ватып бетерү; өстенә басып изү, яньчү; *растоптать бусы упавшие на пол* — идәнгә төшкән муенсаны таптап ватып бетерү; 2. *просторен.* (кия-кия) таптап, ямьшәйтеп бетерү.

**РАСТОПТА'ТЬСЯ** *сов. просторен.* — киңәеп бетү, тапталып бетү, җәелеп бетү (аяк киеме турында).

**РАСТОПЫ'РЕННЫЙ** — тырпайган, аерылган, киерелгән.

**РАСТОПЫ'РИВАТЬ** *несов. разг.* — к. растопырить.

**РАСТОПЫ'РИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. растопыриться.

**РАСТОПЫ'РИТЬ** *сов. разг.* — тырпайту, аеру, еру; *растопырить пальцы* — бармакларны тырпайту (аеру).

**РАСТОПЫ'РИТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. тырпаю, аерылу, ерылу, ачылу; 2. аякларын еру, җәю, аеру; *сидеть растопырившись* — аякларын аерып утыру.

**РАСТОРГА'ТЬ** *несов. книж.* — к. расторгнуть.

**РАСТОРГА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — бозылу, өзелү (договор).

**РАСТО'РГНУТЬ** *сов. книж.* — 1. өзү, бозу, туктату, гамәлдән чыгару, юкка чыгару; *расторгнуть договор* — договорны юкка чыгару; 2. *перен.* өзү, вату, җимерү; бетерү; *расторгнуть узы дружбы* — дуслыкны өзү; *расторгнуть оковы рабства* — коллык богауларын вату.

◇ **Расторгнуть брак** — аерылышу (никахны гамәлдән чыгару).

**РАСТОРГОВА'ТЬ** *сов. просторен.* — сатып бетерү.

**РАСТОРГОВА'ТЬСЯ** *сов. просторен.* — 1. бик кызу сату итә башлау, бик кызып сәүдә итү; 2. сатып бетерү; 3. *устар. (разжиться)* сату итеп баю.

**РАСТОРГО'ВЫВАТЬ** *несов. просторен.* — к. расторговать.

**РАСТОРГО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. просторен.* — 1. к. расторговаться; 2. *страд.* сатылып бетү.

**РАСТОРЖЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — к. расторгнуть; *расторжение договора* — договорны өзү.

**РАСТОРЖИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — (берәр килешүнең) өзелү мөмкинлеге, гамәлдән чыгарылу (туктатылу, бетерелү) мөмкинлеге.

**РАСТОРМОШИ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. *просторен.* актарып ташлау, туздырып ташлау; 2. селкеткәләп уяту, төрткәләп уяту; борчу, борчып бетерү; 3. *перен. фам.* эшкә кузгату, хәрәкәткә китерү, җилкендерү.

**РАСТОРО'ПНОСТЬ** *ж. мн.* нет — җитезлек, өлгерлек, булдыклылык, үткенлек.

**РАСТОРО'ПНЫЙ** *разг.* — җитез, өлгер, үткен, булган, булдыклы.

**РАСТОЧА'ТЬ** *несов. книж.* — 1. әрәм-шәрәм итү, түгү-чәчү, туздыру, таратып бетерү, исраф итү; *расточать имущество* — милекне әрәм-шәрәм итү; 2. бушка уздыру, әрәм итү; *расточать время* — вакытны бушка уздыру. ◇ **Расточать похвалы** — мактаулар яудыру. **Расточать ласки** — чиктән ашып иркәләү. **Расточать речи любви** — мәхәббәт сүзләре чәчү. **Расточать благодеяния** — артык юмартлану.

**РАСТОЧА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — әрәм-шәрәм ителү, туздырылу, исраф ителү.

**РАСТОЧЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — к. расточать.

**РАСТОЧИ'ТЕЛЬ** *м. книж.*, **РАСТОЧИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж. книж.* — әрәм-шәрәм итүче, туздыручы, бәрәкәтсез тотучы, исраф итүче (әйберне, акчаны).

**РАСТОЧИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — әрәм-шәрәм итү(челек), туздыру(чылык), исраф итү(челек); саксыз тоту, бәрәкәтсез (экономиясез) тоту.

**РАСТОЧИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — әрәм-шәрәм итүчән, туздыручан, исраф итүчән, бәрәкәтсез (саксыз, экономиясез) тотучы; *расточительный человек* — исраф итүчән кеше.

**РАСТОЧИ'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет, *неодобр. книж.* — к. расточительность.

**РАСТОЧИ'ТЬ** I *сов.* — 1. *тех.* (кискеч белән) кырып киңәйтү, кырып тирәнәйтү; кырып эшкәртү; *расточить отверстие* — тишекне кырып киңәйтү; 2. (су) юу, ашау; ашап (юып) җимерү; *вода расточила берег* — ярны су юып җимергән.

**РАСТОЧИ'ТЬ** II *сов. книж.* — к. расточать.

**РАСТОЧИ'ТЬСЯ** *сов. тех.* — кырылып киңәю (зураю, тирәнәю).

**РАСТО'ЧКА** *ж. мн.* нет, *тех.* — кыру, кырылу; *расточка отверстия* — тишекне кыру, тишекнең кырылуы.

**РАСТО'ЧНЫЙ** *тех.* — кыру...-ы; кырып эшкәртә торган, кыра торган; *расточный станок* — кыру станогы.

**РА'СТРА** *ж. муз.* — растра, сызгыч (нота кәгазенә янәшә сызыклар сызу коралы).

**РАСТРАВИ'ТЬ** *сов.* — 1 аздыру, ярсыту; авыртуын кузгатып җибәрү; *растравить рану* — яраны аздыру; 2. *перен. разг.* яңадан кузгату, искә төшерү; *растравить старое горе* — иске кайгыны яңадан кузгату; 3. *просторен. (раздразнить)* үртәү, котырту, ярсыту; өсләтү, ырлату (этне), 4. *тип.* (кислота белән) уйдыру, кистерү, ашату.

**РАСТРАВИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *разг.* азып китү, бозыла (эренли, шешә) башлау

2. *тип.* (кислота белән) ашалу, уелу, киселү; *рисунок хорошо растравился* — рәсем бик яхшы уелган.

**РАСТРАВЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — к. растравить 1, 4.

**РАСТРА'ВЛИВАТЬ** *несов.*, **РАСТРАВЛЯТЬ** *несов.*— к. растравить.

**РАСТРА'ВЛИВАТЬСЯ** *несов.*, **РАСТРАВЛЯТЬСЯ** *несов.*—1. к. растравиться; 2. *страд.* ярсытылу, аздырылу, (авыртуы, сызлавы) кузгатылу; 3. *страд. перен.* (йөрәк ярасы) яңадан кузгатылу, искә төшерелү; 4. *страд. простореч.* өсләтелү, үртәтелү, котыртылу (эт турында); 5. *страд. тип.* (кислота белән) ашатылу, уйдырылу (шулай рәсем ясалу).

**РАСТРА'ВЩИК** *м. спец.*— бизәк уючы (туку промышленностенда кислота белән ашатып бизәк ясаучы эшче-белгеч).

**РАСТРАНЖИ'РОВАТЬ** *несов. разг.*— туздыру, әрәм-шәрәм итү, түгү-чәчү, юкбарга тарату, җилгә очыру.

**РАСТРАНЖИ'РИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— 1. к. растранжириться; 2. *страд.* туздырылу, әрәм-шәрәм ителү.

**РАСТРАНЖИ'РИТЬ** *сов.*— туздырып (таратып) бетерү, әрәм-шәрәм итеп бетерү, түгеп-чәчеп бетерү, исраф итеп бетерү.

**РАСТРАНЖИ'РИТЬСЯ** *сов.*— әрәм-шәрәм булып бетү, туздырылып бетү, исраф ителү.

**РАСТРА'ТА** *ж.*— 1. *только ед.* к. растратить; 2. растрата (а. дәүләт акчасын яки милкен үз файдасы өчен тоту, туздыру; б. шулай туздырылган акча, өстенә чыккан сума).

**РАСТРА'ТИТЬ** *сов.*— 1. растрата ясау, туздыру, әрәм-шәрәм итеп бетерү; 2. *(потратить)* тоту, түгү; тотып бетерү, сарыф итү (акчаны); 3. *перен.* югалту, бетерү; *растратить здоровье* — сәламәтлекне югалту.

**РАСТРА'ТЧИК** *м.*, **РАСТРА'ТЧИЦА** *ж.*— растрата ясаучы, туздыручы, әрәм-шәрәм итүче.

**РАСТРА'ЧИВАТЬ** *несов.*— к. растратить.

**РАСТРА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— туздырылу, әрәм-шәрәм ителү; тотылу, түгелү, сарыф ителү.

**РАСТРЕВО'ЖИВАТЬ** *несов.*— к. растревожить.

**РАСТРЕВО'ЖИВАТЬСЯ** *несов.*— к. растревожиться.

**РАСТРЕВО'ЖИТЬ** *сов.*— 1. бик нык борчу, тынычсызлау, тынычлыкны бозу; хәвефкә калдыру, шомландыру; тәшвиш салу, борчу салу; *он растревожил всех неприятным сообщением* — ул күңелсез хәбәр әйтеп, барысының йөрәгенә борчу салды; 2. *перен.* (иске яраны) ярсыту, кузгату; *растревожить старую рану* — иске яраны кузгату.

**РАСТРЕВО'ЖИТЬСЯ** *сов. разг.*— бик нык борчылу, бик нык тынычсызлану, тәшвишкә калу, хәвефләнү, шомлану.

**РАСТРЕЗВО'НИТЬ** *сов. простореч., фам. неодобр.*— (берәр нәрсә турында) шау-шу куптару, гайбәт сату, фаш итү, дөньяга тарату, сөйләп чыгу; *по всему городу растрезвонил об их ссоре* — аларның ызгышуы турында бөтен шәһәргә сөйләп чыкты.

**РАСТРЁПА** *м.* и *ж. простореч. пренебр.*— йолкыш, тузгак баш, алама (сәләмә) киенгән кеше.

**РАСТРЁПАННЫЙ** — 1. (об одежде) ертылып беткән, ертык-портык; тузып беткән, өзгәләнгән, тетелеп чыккан, алама-сәләмә; 2. бик таушалган, туздырып бетерелгән; *растрёпанная книга*.— таушалган китап; 3. тузгыган, тузгак; *растрёпанные волосы* — тузгыган чәч, тузгак чәч. ◇ **Растрёпанный вид** — таушалган (йолкыш) кыяфәт. **В растрёпанных чувствах** *разг. фам.*— дулкынланган (борчулы) хәлдә.

**РАСТРЕПА'ТЬ** *сов. простореч.*— 1. *разг. (измять)* таушалдыру, туздырып бетерү; *растрепать платье* — күлмәкне таушалдыру; *растрепать книгу* — китапны туздырып бетерү; 2. туздыру, тузгыту; *растрепать волосы* — чәчен тузгыту; 3. *спец.* тетү, тарап язу, тарап чистарту, тәрәшләү; *растрепать шерсть* — йон язу; *растрепать пеньку* — пәҗе тәрәшләү.

**РАСТРЕПА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. *(измяться)* таушалып бетү, тузып бетү; тетелеп (өзелеп) бетү; *тетрадь растрепалась* — дәфтәр таушалып беткән; 2. тузгу, тузгып бетү; тузгаклану; *волосы растрепались* — чәче тузгып беткән.

**РАСТРЁПКА** *м.* и *ж. разг. фам.*— к. растрёпа. ◇ **Стёпка-растрёпка** — Стёпка-тузгакбаш (XIX йөз балалар әдәбиятында очрый торган персонаж).

**РАСТРЁПЫВАТЬ** *несов.*— к. растрепать.

**РАСТРЕПЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. *разг.* к. растрепаться; 2. *страд.* таушалдырылу, тузгытылу, туздырылу.

**РАСТРЕ'СКАТЬСЯ** *сов.*— 1. ярылып бетү, ярганланып (чатнап) бетү; *потолок растрескался* — түшәм ярганланып беткән; 2. *вульг.* комсызланып ашау, комсызланып бүсү, бирәнен тыгу (шартлардай булганчы).

**РАСТРЕ'СКИВАТЬСЯ** *несов.*— к. растрескаться.

**РАСТРЕ'СНУТЫЙ** — ярык, ярганланган, ярылган, чатнаган.

**РАСТРО'ГАННЫЙ** — дулкынланган, күңеле йомшарган, күңеле тулган, күңеле нечкәргән, тәэсирләнгән, әсәрләнгән, тойгыларга бирелгән; *сказал растроганным голосом* — дулкынланган тавыш белән әйтте.

**РАСТРО'ГАТЬ** *сов.*— дулкынландыру, күңелне йомшарту, күңелне нечкәртеп җибәрү, бик нык тәэсир итү.

**РАСТРО'ГАТЬСЯ** *сов.*— дулкынлану, күңел йомшару, күңел нечкәрү, күңел тулу; хискә бирелеп китү; бик нык тәэсирләнү, әсәрләнү.

**РАСТРУ'Б** *м. спец.*— раструб (труба, көпшә, моржаның һ. б. ш. бүрәнкәсыман киңәеп киткән авызы).

**РАСТРУБИ'ТЬ** *сов. разг. фам.*— шаулау; хәбәр тарату, шаулап йөрү, сөйләп йөрү; *об этом раструбили по всему городу* — бу турыда бөтен шәһәргә шауладылар.

**РАСТРУ'БНЫЙ** *тех.*— (авызы, очы) киңәеп килгән, бүрәнкә рәвешендәге, бүрәнкәсыман, киңәйгән авызлы; *раструбные трубы* — киңәйгән авызлы трубалар.

**РАСТРУСИ'ТЬ** *сов.*— 1. *разг.* (селкетеп) кою, коя килү, коеп бару; коеп бетерү, әрәм-шәрәм итү, түгеп-чәчеп бетерү; 2. *спец.* тигезләп тарату, таратып җәеп кую; *раструсить сено* — печәнне тигезләп тарату.

**РАСТРУСИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— (селкенеп) коелу, түгелү, чәчелү.

**РАСТРУ'СКА** *ж. мн.* нет — 1. *разг.* к. раструсить; 2. *торг.* коелдык, коелып киму (бөртекле әйберләр белән эш иткәндә түгелү, чәчелү, коелу сәбәпле булган югалтулар).

**РАСТРУ'ШИВАТЬ** *несов.*— к. раструсить.

**РАСТРУ'ШИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. раструситься; 2. *страд.* түгеп-чәчеп бетерелү, әрәм-шәрәм ителү (бөртекле әйберләр турында).

**РАСТРЯСА'ЛЬЩИК** *м.*, **РАСТРЯСА'ЛЬЩИЦА** *ж. спец.*— тәмәке төюче, тәмәке чистартучы (тәмәке фабрикасындагы эшче).

**РАСТРЯСА'ТЬ** *несов.*— к. растрясти.

**РАСТРЯСТИ'** *сов.*— 1. *(рассыпать тряской)* селкетеп кою, коеп бетерү, түгеп-чәчеп бетерү; 2. *разг.* тигезләп тарату, таратып ташлау, таратып җәю, җәеп чыгу; 3. *перен. разг. фам.* юк-барга тотып бетерү, таратып бетерү, түгеп-чәчеп бетерү, әрәм-шәрәм итү, исраф итү, туздыру; *растрясти деньги* — акчаны түгеп-чәчеп бетерү; 4. *(тряся, разбудить)* селкетеп (төрткәләп) уяту, исенә китерү, аңына китерү; 5. *перен. простореч. фам.* кузгату, җан кертү, җанландырып җибәрү; 6. *безл.* (селкетеп) алҗыту, арыту, йончыту; *в дороге меня растрясло* — юлда селкетеп бик арытты.

**РАСТРЯ'СЫВАТЬ** *несов. редко* — к. растрясти.

**РАСТРЯХА'ТЬ** *несов. обл. простореч.*— 1. к. растрясать; 2. к. растряхивать.

**РАСТРЯ'ХИВАТЬ** *несов. разг.*— селеккәләү, каккалау (мәсәлән, киемнең тузанын).

**РАСТРЯХНУ'ТЬ** *сов. разг.* — бик нык селкү, тузанын кагу, кагып алу, селкеп кую; *растряхнуть шубу* — туныың тузанын кагу.

**РАСТУЖИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.*— артык кайгыру, кайгы-хәсрәткә төшү, күңел төшү, кайгыга калу (бату); бик нык пошыну, хәсрәтләнү, сагышлану; аһ-ваһ килү.

**РАСТУШЕВА'ТЬ** *сов. спец.*— 1. *(тушью)* тушьлау, тушь салу; тушь сөртеп чыгу, тушь белән тигезләп буяу, буяп чыгу; 2. *(карандашом)* каралту, каралтып чыгу, күләгәләп чыгу (рәсемнең тиешле урыннарын карандаш белән буяп чыгу).

**РАСТУШЁВКА** *ж. спец.*— 1. *только ед.* к. растушевать; 2. *живоп. спец. (палочка для тушовки)* тушь таягы, тушь каләме (рәсемгә күләгә салу өчен).

**РАСТУШЁВЫВАТЬ** *несов. спец.*— к. растушевать.

**РАСТУШЁВЫВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— 1. тушь салыну, тушь белән буялу; 2. карандаш белән каралтылу, күләгә салыну (рәсемнең тиешле урыннарына).

**РАСТУ'ШКА** *ж.*— к. растушёвка.

**РАСТЫ'КАТЬ** *сов. простореч.*— 1. (төрле җиргә) тыгу, кадау; тыгып (кагып, утыртып) чыгу; *растыкать колышки* — кечкенә казыклар утыртып чыгу; 2. *неодобр.* тәртипсез урнаштыру, тыккалап кую, кая туры килсә шунда тыгу; *растыкать книги по полкам* — китапларны киштәләргә тыккалап кую.

**РАСТЫКА'ТЬ** *несов. простореч.*— к. растыкать.

**РАСТЫКА'ТЬСЯ** *несов. страд. простореч.*— (төрле урынга) кагып куелу, кадап (утыртып) чыгылу; тыккалап куелу.

**РАСТЫ'КИВАТЬ** *несов. простореч.*— к. растыкать.

**РАСТЫ'КИВАТЬСЯ** *несов. страд. простореч.*— к. растыкаться.

**РАСТЮКОВА'ТЬ** *сов. спец.*— тюкны чишү, төенне ачу, төргәкне сүтү.

**РАСТЮКО'ВЫВАТЬ** *несов. спец.*— к. растюковать.

**РАСТЮКО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— чишелү, сүтелү, ачылу (төргәк, тюк).

**РАСТЯ'ГИВАТЬ** *несов.*— к. растянуть.

**РАСТЯ'ГИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. растянуться; 2. *страд.* тартып сузылу, озынайтылу; киереп (тарттырып) җәеп куелу.

**РАСТЯЖЕ'НИЕ** *ср.*— 1. *только ед.* к. растянуть 1, 2, 3, 4, 5, 6; 2. *мед.* (сеңер, тамыр) тартылу, тартылып имгәнү; *растяжение связок* — сеңерләрнең тартылуы.

**РАСТЯЖИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— 1. сузылучанлык, сузылмалылык; сузылу (тартылу)сәләте; *растяжимость резины* — резинаның сузылучанлыгы; 2. *перен.* төрлечә аңларга мөмкин булу, аныксызлык; *растяжимость понятия* — төшенчәнең аныксызлыгы (төрлечә аңлануы).

**РАСТЯЖИ'МЫЙ** — 1. сузылмалы, сузылучан, сузыла (озыная) торган; 2. *перен.* аныксыз, тәгаллексез, төрле мәгънәгә борып була торган, төрлечә аңлашыла торган; *растяжимое понятие* — аныксыз (төрлечә аңлап була торган) төшенчә.

**РАСТЯ'ЖКА** *ж. мн.* нет, *разг.*— к. растянуть 1, 2, 3.

**РАСТЯЖНО'Й** *спец.*— тартыла торган, (тартып) сузыла торган, озыная торган, сузылмалы.

**РАСТЯ'НУТОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— 1. озынлык; сузылган (җәелгән) булу; сузылыш, җәелеш; *растянутость линии фронта* — фронт линиясенең бик сузылган булуы; 2. *перен.* озын булу, артык озын булу, сузынкы булу; *растянутость рассказа* — хикәянең артык озын булуы.

**РАСТЯ'НУТЫЙ** — 1. бик озынга сузылган, сузылып киткән, озаеп киткән; *растянутый фронт* — бик озынга сузылган фронт; 2. *перен.* артык озын, сузынкы, эчпошыргыч озын; *растянутый рассказ* — эчпошыргыч озын хикәя.

**РАСТЯНУ'ТЬ** *сов.*— 1. (як-якка) тарту,

сузу; тартып зурайту, сузып озынайту; тарттырып (калыпка салып) киңәйтү; киерү, киереп зурайту, киергечләү, киергечләп (тарттырып) кую; *растянуть сырую кожу* — чи тирене тарттырып кую; 2. җәю, җәеп кую, җәеп ташлау; *растянуть полотно для сушки* — киндерне киптерү өчен җәеп кую; 3. сузу, озакка сузу; озак йөртү, озак эшләү, тартып-сузып йөртү; *растянуть доклад на два часа* — докладны ике сәгатькә сузу; 4. артык сузып (җәелдереп, таратып) урнаштыру; *наш полк сильно растянули* — безнең полкны артык сузып урнаштырганнар (артык сузылдырганнар); 5. *простореч. фам.* (*в борьбе*) сузып салу, егып салу, күтәреп бәрү.

**РАСТЯНУ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. (тартылып) озынаю, сузылу, киерелү, зураю; киңәеп китү; 2. сузылып бетү, сузылмас булып (бушап) калу; *подвязки растянулись* — бәйләргычлар сузылып бетте (сузылмас булды); 3. озакка сузылу, озакка тартылу; *доклад растянулся* — доклад озакка сузылды; 4. *разг. фам.* сузылып яту; *растянулся на диване* — диванга сузылып ятты; 5. сузылу, сузылып китү, киң арага җәелү, киң урнашу; *линия фронта сильно растянулась* — фронт линиясе бик нык сузылган; 6. *разг.* сузылып барып төшү, лап итеп егылу.

**РАСТЯ'ПА** *м.* и *ж. простореч. фам.*— булмаган, пешмәгән, җебегән, ачык авыз, җобалгы (кеше).

**РАСТЯ'ПАТЬ** *сов. простореч.*— чабу, кисеп (чабып) чыгару.

**РАСТЯ'ПЫВАТЬ** *несов. простореч.*— чабу, кисү.

**РАСТЯ'ПЫВАТЬСЯ** *несов. страд. простореч.*— кисеп (чабып) чыгарылу, чабылу.

**РАСФАСОВА'ТЬ** *сов. торг. спец.*— (үлчәп) төрү, пачкалау, пакетларга салу, фасовать итү.

**РАСФАСО'ВКА** *ж. мн.* нет, *торг.*— к. расфасовать.

**РАСФАСО'ВЩИК** *м.*, **РАСФАСО'ВЩИЦА** *ж. торг. спец.*— фасовать итүче, ваклап төрүче (товарларны үлчәп пакетларга төрүче).

**РАСФАСО'ВЫВАТЬ** *несов. торг. спец.*— к. расфасовать.

**РАСФАСО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд. торг. спец.*— ваклап төрелү, фасовать ителү (пачка, пакет, кап һ. б. салып төрелү).

**РАСФОРМИРОВА'НИЕ** *ср.*— к. расформировать, расформировываться.

**РАСФОРМИРО'ВАННЫЙ** — 1. *воен.* таратылган, бетерелгән; 2. *ж.-д.* (*о поезде*) таратылган (вагоннар тиешле юлларга таратып куелган).

**РАСФОРМИРОВА'ТЬ** *сов. офиц.*— 1. *воен.* тарату, таратып җибәрү, бетерү; 2. *ж.-д.* (поездның вагоннарын аерып) тиешле юлларга тарату, таратып кую.

**РАСФОРМИРОВА'ТЬСЯ** *сов.*— таралу, бетү.

**РАСФОРМИРО'ВКА** *ж. мн.* нет, *разг.*— к. расформировать.

**РАСФОРМИРО'ВЫВАТЬ** *несов. офиц.*— к. расформировать.

**РАСФОРМИРО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. спец.*— 1. к. расформироваться; 2. *страд.* таратылу, таратып җибәрелү, бетерелү; 3. *ж.-д.* (вагоннар) тиешле юлларга таратып куелу.

**РАСФРАНТИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— фырт киенү, киенү-ясану, купшы киенү, баштанаяк мода буенча киенү.

**РАСФРАНЧЁННЫЙ** *разг.*— бик фырт, купшы киенгән, киенгән-ясанган, яңа мода белән киенгән, франтларча киенгән.

**РАСФУФЫ'РЕННЫЙ** *простореч. ирон.*— чиктән тыш купшы киенгән, чиктән тыш киенгән-ясанган.

**РАСФУФЫ'РИТЬСЯ** *сов. простореч. ирон.*— артык купшы киенү, чиктән тыш киенү-ясану.

**РАСХА'ЖИВАТЬ** *несов.*— йөренү, йөреп тору, әрле-бирле йөрү; *расхаживать взад и вперёд по комнате* — бүлмә буйлап ишекле-түрле йөренү.

**РАСХА'ИВАТЬ** *несов. простореч.*— к. расхаять.

**РАСХА'ИВАТЬСЯ** *несов. страд. простореч.*— яманланылу, начар бәя бирелү.

**РАСХА'ЯТЬ** *сов. простореч.*— яманлау, яманлап бетерү, начар бәя бирү.

**РАСХВА'ЛИВАТЬ** *несов.*— к. расхвалить.

**РАСХВА'ЛИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. расхвалиться; 2. *страд.* бик нык макталу.

**РАСХВАЛИ'ТЬ** *сов.*— бик нык мактау, чиктән тыш мактау, артык мактап җибәрү, мактап ташлау; мактап-мактап сөйләү, күкләргә күтәреп мактау.

**РАСХВАЛИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— мактану, үзен-үзе мактау, лаф ору, шапырыну, мактанып сөйләү.

**РАСХВА'РЫВАТЬСЯ** *несов. разг.*— к. расхвораться.

**РАСХВА'СТАТЬ** *сов. простореч.*— к. расхвастаться.

**РАСХВА'СТАТЬСЯ** *сов.*— мактана (шапырына) башлау, мактанып сөйләү, лаф ору.

**РАСХВАТА'ТЬ** *сов. разг.*— (ашыга-ашыга) алып бетерү, ябырылып алып бетерү, сатып алып бетерү; *новые книги расхватали за два часа* — яңа китапларны ике сәгать эчендә сатып алып бетерделәр.

**РАСХВАТИ'ТЬ** *сов. простореч.*— к. расхватать.

**РАСХВА'ТЫВАТЬ** *несов.*— к. расхватать.

**РАСХВА'ТЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— (ашыга-ашыга) алып бетерелү, сатып алып бетерелү.

**РАСХВОРА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— каты авырый башлау, бик нык авырып китү; озаклап авыру, авырып (сырхаулап) яту, хасталану.

**РАСХИТИ'ТЕЛЬ** *м. книж.*— урлаучы, туздыручы.

**РАСХИ'ТИТЬ** *сов. книж.*— урлау, талау, урлап бетерү.

**РАСХИЩА'ТЬ** *несов. книж.*— к. расхитить.

**РАСХИЩА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.*— урлану, талану, урлап (талап) бетерелү.

**РАСХИЩЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— к. расхитить.

**РАСХЛЕБА'ТЬ** *сов. простореч. фам.*— 1. ашау, ашап бетерү, эчеп бетерү (сыек ашны); *расхлебать щи* — щины ашап бетерү; 2. *перен.* ерып чыгу, очына чыгу, хәл итү; *этой истории одному не расхлебать* — бер кеше генә бу вакыйганың очына чыгарлык түгел.

**РАСХЛЁБЫВАТЬ** *несов. простореч. фам.* — к. расхлебать.

**РАСХЛЁБЫВАТЬСЯ** *несов. страд. простореч. фам.*— ашап бетерелү, эчеп бетерелү (сыек аш турында).

**РАСХЛЕСТНУ'ТЬ** *сов. разг.*— чалынганны ычкындыру, эләккәнне ычкындырып җибәрү; *расхлеснуть верёвку* — эләккән бауны ычкындыру.

**РАСХЛЕСТА'ТЬ** *сов. простореч.*— (суга-суга яки шартлата-шартлата) мунчалаландырып бетерү, сүсәртеп бетерү, туздырып бетерү, эштән чыгарып бетерү; *расхлестать кнут* — камчыны туздырып бетерү.

**РАСХЛЕСТА'ТЬСЯ** *сов. простореч.*— 1. тузып бетү, мунчалаланып бетү; *кнут совсем расхлестался* — чыбыркы бөтенләй мунчалаланып беткән; 2. бик каты чыбыркылый башлау; (чыбыркы белән) кызып-кызып кыйнау, яру.

**РАСХЛЁСТЫВАТЬ** *несов.*— 1. к. расхлеснуть; 2. расхлестать.

**РАСХЛЁСТЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. *простореч.* к. расхлестаться; 2. *страд.* (эләккән, чалынган) ычкындырылу, чишеп (сүтеп) җибәрелү; 3. *страд.* (суга-суга) эштән чыгарылу, мунчалаландырып (сүсәртеп) бетерелү.

**РАСХЛОПОТА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— бик нык кайнаша башлау, ыгы-зыгы килә башлау; *хозяйка расхлопоталась у печи* — хуҗа хатын мич янында кайнаша башлады.

**РАСХЛЯ'БАННОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. *разг.* таркалганлык, чыгырыннан (эзеннән) чыккан булу; *расхлябанность хозяйства* — хуҗалыкның таркалганлыгы; 2. *разг.* какшаганлык, рәте киткән булу; *расхлябанность здоровья* — сәламәтлекнең какшаганлыгы; 3. эленке-салынкылык; *расхлябанность походки* — йөрешнең эленке-салынкылыгы; 4. таркаулык, оешмаганлык, тәртипсезлек; *расхлябанность на производстве способствует вредителям* — эштәге таркаулык корткычларга ярдәм итә.

**РАСХЛЯ'БАННЫЙ** *разг.*— 1. селкенә торган, какшаган, буша(й)ган; 2. *перен.* мәлҗеган, эленке-салынкы, алкы-салкы; *расхлябанная походка* — алкы-салкы йөреш; 3. *перен.* зәгыйфь, какшаган, рәте киткән, чыгырыннан чыккан; *расхлябанное здоровье* — какшаган сәламәтлек; 4. *перен. неодобр.* таркау, җобалгы; тәртипсез, дисциплинасыз; *расхлябанное поведение* — үзен тәртипсез тоту.

**РАСХЛЯ'БАТЬ** *сов. разг.*— 1. *(расшатать тряской)* селкетеп какшату, бушайту (мәсәлән, винтны); 2. *перен. неодобр.* тәртипсезлек (таркаулык) кертү; чыгырыннан чыгару, эштән чыгару, харап итү, таркату; *расхлябать хозяйство* — хуҗалыкны таркату; 3. *перен. неодобр.* какшату; *расхлябать здоровье* — сәламәтлекне какшату.

**РАСХЛЯ'БАТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. какшау, бушау, бушап бетү, какшап бетү; *гайка расхлябалась* — гайка бушаган; 2. *перен.* *(о хозяйстве)* таркалу, җимерелү, харап булу, эзеннән чыгу, эштән чыгу; 3. *перен.* какшау, зәгыйфьләнү, начарлану, рәте китү; *расхлябалось здоровье* — сәламәтлекнең рәте китте; 4. *перен. неодобр.* *(распуститься)* тәртипсезләнү, чыгырдан чыгу, азу, бозылып бетү, йөгәнсезләнү.

**РАСХЛЯ'БЫВАТЬ** *несов. разг.*— к. расхлябать.

**РАСХЛЯ'БЫВАТЬСЯ** *несов. разг.*— 1. к. расхлябаться; 2. *страд.* какшатылу, бушайтылу, таркатылу.

**РАСХНЫ'КАТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. *(начать хныкать)* шыңшый башлау, шыңшырга тотыну, шыңшып елый башлау; 2. *перен.* *(жаловаться)* зарлану, сукрана башлау, зарланып сөйләү.

**РАСХО'Д** *м.*— 1. *только ед. разг.* таралу, тарату; *издавать журнал по самой дешёвой цене для большего расхода* — күбрәк таралсын өчен журналны иң арзан бәя белән чыгару; 2. расход, чыгым; *приход и расход* — керем һәм чыгым; 3. *бухг. канц.* чыгым бүлеге (бухгалтерия кенәгәләрендә); 4. (акча һ. б.) тоту, тотылу, сарыф итү; (акча) чыгу, китү; *расход пара* — парның тотылуы (эшкә күпме пар китүе); 4. *торг. разг.* сатылу, үтем; базары булу, яхшы сатыла торган булу; *на этот товар большой расход* — бу товарның үтеме зур (ягъни бу бик үтемле товар); 5. *тех.* ачыклык, аралык (машинаның хәрәкәт итә торган частьларының иркен йөрүе өчен калдырылган бушлык). ◇**Вывести в расход** *просторе.*— ат(тыр)у, атып үтер(т)ү, расходка чыгар(т)у.

**РАСХОДИ'ТЬСЯ** I *сов. разг.*— 1. *(привыкнуть к ходьбе)* йөри-йөри күнегү; 2. күп йөрү; еш йөри башлау, (әрле-бирле) йөренә башлау; киләп сарып йөрү; *расходились по коридору* — коридор буйлап йөренә башладылар; 3. кочәю, котыра башлау, кызып китү, көчәеп китү; *буря расходилась* — давыл көчәеп китте; 4. типтерү, әйттерү; эчү, кәеф-сафа кору; *расходился парень на радостях* — егет шатлыгыннан типтерә; 5. *(рассердиться)* ачулану, бик нык кызу, котырыну; *(раскричаться)* җикерену, кычкырыну.

**РАСХОДИ'ТЬСЯ** II *несов.*— к. разойтись.

**РАСХО'ДНЫЙ** — расход...-ы; чыгым...-ы; *расходная книга* — расход кенәгәсе (чыгымнарны язу кенәгәсе); *расходная статья* — чыгымнар статьясы.

**РАСХО'ДОВАНИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— к. расходовать.

**РАСХО'ДОВАТЬ** *несов.*— 1. чыгым тоту, акча тоту, расход чыгару, расход ясау; тоту, сарыф итү; *расходовать деньги* — акча

тоту; 2. бетерү, китү; *лампа расходует много керосину* — лампа бик күп керосин бетерә.

**РАСХО'ДОВАТЬСЯ** *несов.* — 1. расходлану, чыгымлы булу; акча тоту, сарыф итү, расход (чыгым) тоту; *я не могу так расходоваться на развлечения* — күңел ачулар өчен мин алай акча тота (туздыра) алмыйм; 2. *страд.* тотылу, туздырылу, сарыф ителү.

**РАСХОЖДЕ'НИЕ** *ср. книж.* — 1. к. разойтись 8, 9, 10, 11; 2. юл чаты, юл аерылышы, юл аермасы; 3. аймылыш, аймыл булу, очрашмау; 4. ара өзелү; бозылышу; 5. каршылык, башкалык; капма-каршылык, килешмәүчәнлек; *расхождение во взглядах* — карашлар каршылыгы, фикер башкалыгы; 6. аерма, аерымлык, туры килмәү; *расхождение между приходом и расходом* — керем белән чыгымның туры килмәве.

**РАСХО'ЖИЙ** *разг.* — 1. үтемле, сатыла торган; *расхожий товар* — үтемле товар; 2. көн дә кулланыла торган, көн дә тотыла торган; *расхожая посуда* — көн дә кулланыла торган савыт-саба; 3. көндәлек, көн дә киелә торган; *расхожая одежда* — көндәлек кием.

**РАСХОЛА'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. расхолодить.

**РАСХОЛА'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — күңеле суындырылу, күңеле кайтарылу.

**РАСХОЛОДИ'ТЬ** *сов.* — күңелен суындыру, күңелен кайтару, күңелен төшерү; гайрәтен чигерү, эшкә теләген (һәвәсен) бетерү, рухны төшерү; араны салкынайту; *неудача его расхолодила* — уңышсызлык аның күңелен суындырды.

**РАСХОРОХО'РИТЬСЯ** *сов. разг.* — әтәчләнеп китү, кәпрәеп китү; кукыраю, кәпәренү.

**РАСХОТЕ'ТЬ** *сов. разг.* — теләк бетү, теләми башлау, күңел кайту, ...-мас булу; *я расхотел есть* — минем ашаудан күңелем кайтты (ашамас булдым).

**РАСХОТЕ'ТЬСЯ** *сов. безл. разг.* — ...-сы килми башлау; *мне расхотелось спать* — минем йоклыйсым килми башлады (йокым качты).

**РАСХОХОТА'ТЬСЯ** *сов.* — хахылдап көлә башлау, шаркылдап көлеп җибәрү; бертуктамый көлү; *что ты расхохотался?* — нәрсә син бертуктамый көләсең дә көләсең?

**РАСХРАБРИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — батырланып китү, гайрәтләнеп китү, батыраеп китү, кыюлану; батырлык күрсәтү; *смотри, как расхрабрился!* — кара син аны, ничек батырланып китте!

**РАСХРАПЕ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — бик нык гырылдый башлау, гырлап йокыга китү.

**РАСХУЛИ'ТЬ** *сов. устар. простореч.* — бик нык яманлау, хурлау, бетереп ташлау; бик нык шелтәләү, сүгеп ташлау, тиргәп ташлау.

**РАСЦАРА'ПАТЬ** *сов.* — 1. тырнау, тырнап бетерү; тырнап алу, тырнап ерту; *кошка ребёнку все руки расцарапала* — мәче баланың бөтен кулын тырнап бетергән; 2. (әләктереп) тырнату, сыдырту, сыдыртып бетерү; *расцарапал руку гвоздём* — кулымны кадакка сыдырттым.

**РАСЦАРА'ПАТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. тырналу, тырналып бетү; 2. (бер-берсен) тырнау, тырнап бетерү; тырнашу, тырнашып бетү; *две снохи расцарапались* — ике килендәш бер-берсен тырнап бетергәннәр; 3. *перен. фам.* (*рассориться*) ызгышу, талашу.

**РАСЦАРА'ПЫВАТЬ** *несов.* — к. расцарапать.

**РАСЦАРА'ПЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. расцарапаться.

**РАСЦВЕСТИ'** *сов.* — 1. чәчәк ату; *расцвела липа* — юкә чәчәк атты; 2. *перен.* тазарып (алсуланып, тулыланып, сәламәтләнеп) китү; матурланып китү; 3. яктырып китү, нурланып (ачылып) китү; *лицо расцвело улыбкой* — елмаюдан йөзе яктырып китте; 4. *перен.* гөрләп чәчәк ату, алга китү, киң үсеш алу; күтәрелү, алга ашу; тәрәккъый итү; *в нашей стране расцвели науки и искусства* — безнең илебездә фән һәм сәнгать чәчәк атты.

**РАСЦВЕ'Т** *м.* — 1. чәчәк ату, чәчәкләнү, гөлләнү; чәчәк вакыты, чәчәк аткан чак; *полный расцвет яблонь* — алмагачның чәчәк аткан вакыты (шау чәчәктә утырган чагы); 2. *перен.* иң югары үсеш, күтәрелеш, алга китеш, алгарыш, чәчәк ату чоры; *социализм есть период расцвета национальных культур* — социализм милли культураларның чәчәк ату чоры ул. ◇ **В расцвете сил** — көче ташып торганда.

**РАСЦВЕТА'НИЕ** *ср. мн. нет, книж.* — к. расцветать, расцвет.

**РАСЦВЕТА'ТЬ** *несов.* — к. расцвести.

**РАСЦВЕТИ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. төрле төскә буяу, чуарлау, бизәкләү, бизәк төшерү; *расцветить красками* — төрле буяулар белән буяу; 2. төрле төстәге...-лар белән бизәү, бизәп кую, бизәп чыгу; *расцветить флагами* — төрле төстәге флаглар белән бизәү.

**РАСЦВЕ'ТКА** *ж. разг.* — 1. *только ед.* к. расцветить; 2. төс, бизәк; чәчәкләр, парчалар (ситсыда); буялыш, бизәкләнеш (буяулар сайланышы, төсләр җыелмасы); *шёлк яркой расцветки* — бик ачык төсле ефәк; *у этой материи неприятная расцветка* — бу материянең бизәкләре күңелгә ятышсыз.

**РАСЦВЕ'ЧИВАТЬ** *несов. разг.* — к. расцветить.

**РАСЦВЕ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — (төрле төсләргә) буялу, бизәлү; чуарлап буялу, төрле төсле бизәкләр төшерелү.

**РАСЦЕЛОВА'ТЬ** *сов.* — (бик каты) үбү, күп тапкыр үбү, үбеп-үбеп алу, үбеп бетерү, суырып-суырып үбү; *расцеловать ребёнка* — баланы суырып-суырып үбү.

**РАСЦЕЛОВА'ТЬСЯ** *сов.* — үбешү, үбешеп чыгу.

**РАСЦЕЛО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. расцеловать.

**РАСЦЕЛО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. расцеловаться.

**РАСЦЕ'НИВАЕМЫЙ** — 1. ... тора торган, ... -лык; бәясе (хакы) ... булган; *расцениваемый в сто рублей* — йөз сум тора торган;

2. *перен.* ... дип бәяләнә торган, хисаплана (карала) торган.

**РАСЦЕ'НИВАТЬ** *несов.* — к. расценить.

**РАСЦЕ'НИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — бәялəнү, бәя бирелү, бәя куелу; каралу, билгеләнү, ... дип хисаплану, саналу.

**РАСЦЕНИ'ТЬ** *сов.* — 1. *торг.* бәяләү, бәя кую, бәяләп чыгу; хакын (бәясен) билгеләү, кыйммәтен (купме торганын) билгеләү; *расценить работу по высшей ставке* — эшне иң югары бәя белән бәяләү; 2. *перен.* бәя бирү, бәяләү; ... дип хисаплау, карау; *как расценить такое поведение?* — бу кыланышны ни дип бәяләргә?

**РАСЦЕ'НКА** *ж.* — 1. *только ед.* к. расценить 1; *расценка товаров* — товарларга бәя кую; 2. куелган бәя, хак, бәһа; *продавать по низкой расценке* — түбән бәя белән сату; 3. (*ставка*) эшнең хакы, эшкә түләү (эш башыннан эшләгәндә эшнең алдан билгеләнгән хакы).

**РАСЦЕ'НОК** м. *простореч.* — к. расценка 2, 3.

**РАСЦЕ'НОЧНЫЙ** — бәяләү...-ы; бәя кую...-ы; бәя (хак) билгеләү...-ы; *расценочная комиссия* — бәяләү комиссиясе. ◇ **Расценочно-конфликтная комиссия** — бәяләү һәм конфликтлар тикшерү комиссиясе.

**РАСЦЕ'НЩИК** *м. спец.* — бәя куючы.

**РАСЦЕНЯ'ТЬ** *несов. простореч.* — к. расценить 1.

**РАСЦЕПИ'ТЬ** *сов.* — 1. ычкындырып кую, ычкындырып җибәрү; бер-берсеннән аеру, аерып кую, өзеп кую; *расцепить вагоны* — вагоннарны ычкындырып кую; 2. *перен. разг.* аеру, аерып җибәрү; *расцепить драчунов* — сугышучыларны аерып җибәрү.

**РАСЦЕПИ'ТЬСЯ** *сов.* — ычкыну, ычкынып китү; аерылу, өзелү; өзелеп калу, өзелеп чыгу.

**РАСЦЕПЛЕ'НИЕ** *ср.* — 1. к. расцепить, расцепляться; 2. аерылыш, өзелеш.

**РАСЦЕПЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. расцепить.

**РАСЦЕПЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. расцепиться; 2. *страд.* ычкындырылу, ычкындырып җибәрелү; аерып куелу, өзеп куелу.

**РАСЧА'ЛИВАТЬ** *несов. спец.* — к. расчалить.

**РАСЧА'ЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. (причал арканы) чишелү, сүтеп алыну, ычкындырылу; алыну, алып ташлану; 2. *тех.* тарттырылу, тарттырып бәйләп куелу, тарттырып ныгытып куелу; терәк куелу, терәк салыну, ныгытылу.

**РАСЧА'ЛИТЬ** *сов. тех.* — 1. (причал арканын, бавын) чишү, сүтеп ычкындыру; алу, алып ташлау; *расчалить причал* — причал арканын ычкындыру, алып ташлау (пароход кузгалып китү өчен); 2. тарттыру, тарттырып кую, тарттырып ныгыту; терәү, (терәк) белән ныгыту, терәк кую.

**РАСЧА'ЛКА** *ж. тех.* — 1. к. расчалить; 2. *тех.* тарттыргыч, тарттыргыч трос (биек труба һәм мачталарны ныклык-тотрыклык өчен тарттырып беркетеп куйган тимер аркан).

**РАСЧЕКА'НИТЬ** *сов.*, **РАСЧЕКА'НИВАТЬ** *несов.* — 1. *тех.* чүкеп эшкәртү, чүкеп ясау; чүкеп ялгау, (ямау), чүкеп беркетү, ныгыту (металл әйбернең җөйләрен, тоташтырмаларын); 2. *перен.* (сүзләрен) ачык әйтү, ярып әйтү, өзеп әйтү.

**РАСЧЕКА'НИВАТЬСЯ** *несов. страд. тех.* — чүкеп ясалу, чүкеп эшкәртелү (ялгану, ямалу, беркетелү, ныгытылу).

**РАСЧЕКА'НКА** *ж. мн.* нет, *тех. разг.* — 1. к. расчеканить, расчеканиваться; 2. чүкелеш, чүкеп беркетелеш, чүкеп ямалу.

**РАСЧЕКА'НЩИК** *м. спец.* — чүкүче, чүкеп ясаучы, чүкеп эшкәртүче (металл әйберләрнең җөйләрен, тоташтырмаларын эшкәртүче).

**РАСЧЕ'РПЫВАТЬ** *несов.*, **РАСЧЕ'РПАТЬ** *сов.* — сосу, сосып бетерү, сосып алу.

**РАСЧЕРТИ'ТЬ** *сов.* — сызык сызу, сызыклар сызу, сызыклар сызып чыгу.

**РАСЧЕ'РЧИВАТЬ** *несов.* — к. расчертить.

**РАСЧЕ'РЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — сызыклар сызылу, сызыклар сызып чыгылу.

**РАСЧЁС** *м.* — кашылу, тырналу.

**РАСЧЕСА'ТЬ** *сов.* — 1. тарау, тарап кую, тарап җибәрү, тарап бетерү; *расчесать волосы* — чәч тарау; 2. (*шерсть и т. п.*) тарап чистарту, тәрәшләү; 3. кашып куптару; азлыру; *расчесать рану* — яраны кашып куптару; 4. *перен. фам. простореч.* (*побить, победить многих*) кыру, кырып ташлау; тетмәләрен тетү, тетеп салу, кирәкләрен бирү.

**РАСЧЕСА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. чәчен тарау, тарану, (үз-үзенне) тарап төзәтенү; 2. *фам.* кашыну; кашына башлау; кашына бирү, (туктаусыз) кашына башлау.

**РАСЧЁСКА** *ж.* — 1. *только ед.* к. расчесать 1, 2; 2. *разг.* кесә тарагы, расчёска.

**РАСЧЕ'СТЬ** *сов. разг.* — к. рассчитать 1, 2.

**РАСЧЕ'СТЬСЯ** *сов.* — к. рассчитаться 1, 2.

**РАСЧЁСЫВАТЬ** *несов.* — к. расчесать.

**РАСЧЁСЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг.* к. расчесаться; 2. *страд.* таралу, тарап куелу.

**РАСЧЁТ** *м.* — 1. к. рассчитать; 2. исәп, исәпләү, хисаплау; санау; *ошибка в расчёте* — исәптә ялгышу, исәпләүдә ялгышу; 3. исәпләүләр (нәтиҗәсе); *правильный расчёт* — исәпләүләр нәтиҗәсе дөрес; 4. *тех.* хисаплама, расчёт (берәр корылманың проектын төзү өчен кирәк булган санлы мәгълүматларны исәпләп чыгару); *произвести расчёт моста* — күпернең хисапламасын (расчётын) чыгару; 5. исәпләшү, өзелешү, исәп-хисап; счёт буенча түләү; бурычны каплау; *с кредиторами учинён полный расчёт* — кредиторларга счёт буенча тулысынча түләнде; 6. *только ед.* расчёт, эштән чыгу, эштән чыгару, эштән бушату (эш хакын түләп); *дать расчёт служащему* — хезмәткәрне эшеннән чыгару; 7. *перен.* (*расправа*) үч алу, исәп-хисап алу, исәпләшү, кару кайтару, җәза; *будет с барином расчёт* — барин белән исәпләшәсе бар әле; 8. *перен.* уй, ният, теләк, исәп, чама, максат; *был у него расчёт женить меня* — аның мине өйләндерергә нияте бар иде; 9. *разг. только ед.* файда, мәгънә; интерес, кызыксыну, мәнфәгать; *мне нет*

*расчёта ехать туда* — мина анда барудан файда юк; 10. *только ед.* саклык, бәрәкәт; чамалап (исәпләп) тоту; *жить с расчётом* — саклык белән генә яшәү; 11. *воен.* бүлү, аеру; *произвести расчёт эскадрона на звенья* — эскадронны звеноларга бүлү. ◇ **Пулемётный расчёт** *воен.* — пулемёт расчёты (бер пулемётка хезмәт күрсәтүче гаскәриләр төркеме). **Хозяйственный расчёт** *экон.* — хуҗалык исәбе. **По безналичному расчёту** *фин. торг.* — акча күчереп түләп, банк аша түләп. **За наличный расчёт** *фин. торг.* — саф акчага (банк аша түгел, алганда ук түләп). **В расчёте** *с кем-н.* — исәпләштек, бурычлы (тиеш) түгел; *мы с тобой в расчёте* — без исәпләштек. **Из расчёта** — хисабыннан, исәбеннән чыгып, ...-дан чыгып. **Принять в расчёт** *кого-что* — исәпкә алу, искә алу, игътибарга алу, күздә тоту. **Особый расчёт** — аерым исәп-хисап, аерым сөйләшәсе бар. **В расчёте** *на что-н.* — ...-ны күздә тотып; ...-га ышанып, нигезләвеп, ... дигән караштан чыгып, ...дип; *рассказал в расчёте на его скромность* — аның тыйнаклыгына ышанып сөйләп биргән. **С расчётом** — 1. чамалап, исәпләп; 2. (*намеренно*) юри, белә торып, берәр уй (максат) белән. **Без всякого расчёта** — бернинди максатсызнисез, ышерен уйсыз; ахырын уйлап житкермичә. **Копеечный расчёт** — сукыр бер тиенлек эш.

**РАСЧЁТИСТЫЙ** *простореч. обл.* — к. расчётливый.

**РАСЧЁТЛИВО** *нареч.* — исәпләп, саклап, саклык белән; экономия белән, бәрәкәтле итеп; чамалап кына; *расходовать расчётливо* — исәпләп тоту.

**РАСЧЁТЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. (*осмотрительность*) саклык; саклык белән (исәпләп, чамалап) эш итүчәнлек; 2. (*экономность*) экономиялелек; исәп-хисап белән тоту, саклык белән тоту (акчаны, байлыкны).

**РАСЧЁТЛИВЫЙ** — 1. (*бережливый, экономный*) саклык белән тотучы, исәпләп тотучы, кысып тотучы, тота белүче (акчаны); экономияле, бәрәкәт белән тотучы; 2. ахырын уйлап (карап) эш итүче; тирәягын чамалап (исәпләп) эшләүчән; сак, саклык белән эш итүчән; *во всех делах он очень расчётлив* — ул һәр эштә дә бик сак кеше.

**РАСЧЁТНЫЙ** — 1. исәпләү (хисаплау) ...-ы; *расчётная таблица* — исәпләү таблицасы; 2. *бухг.* исәп-хисап ясый торган, түләү...-ы; *расчётная ведомость* — хезмәт хакы түләү исемлеге; 3. *тех.* расчёт...-ы; исәпләү...-ы; *расчётные данные* — расчёт мәгълүматлары. ◇ **Расчётный период** *фин.* — хисап ясала торган чор (тулай исәп-хисап үткәрелә торган вакыт арасы, мәсәлән, ай, ел).

**РАСЧЁТЧИК** *м.*, **РАСЧЁТЧИЦА** *ж. спец.* — расчётчы, расчёт ясаучы (проектларның техник расчётын чыгаручы белгеч-инженер яки архитектор).

**РАСЧЕХВО'СТИТЬ** *сов. простореч. фам.* — к. расчихвостить.

**РАСЧЕХЛИ'ТЬ** *сов. спец.* — чехолын салдыру.

**РАСЧИ'СЛИТЬ** *сов. разг.* — исәпләп чыгару, хисаплап чыгу; исәпләп бүлү, хисаплап бүлгәләп кую.

**РАСЧИСЛЯ'ТЬ** *несов. разг.* — к. расчислить.

**РАСЧИСЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — исәпләп чыгарылу, исәплән(ел)ү, хисаплан(ыл)у.

**РАСЧИ'СТИТЬ** *сов.* — 1. чистарту, тазарту, арчу, арындыру; *расчистить дорогу* — юлны чистарту; *расчистить лес* — урман арчу; 2. *разг. перен.* юл арчу, юл ачып кую, киртәләрне алып ташлау, җирлек хәзерләү; *расчистить путь для победы нового* — яңаның җиңүе өчен җирлек хәзерләү (юл арчу); 3. *простореч. фам.* эштән куу, куып чыгару; *у нас всех прогульщиков расчистили* — бездә барлык прогулчыларны эштән кудылар.

**РАСЧИ'СТИТЬСЯ** *сов.* — чистару, арыну, арчылу; ачылу; ачылып китү; аязу, аязып китү; *небо расчистилось* — күк йөзе ачылып (аязып) китте.

**РАСЧИ'СТКА** *ж. мн.* нет — 1. к. расчистить; 2. *обл.* чистартылган җир, арчылган урман, ышна.

**РАСЧИХА'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.* — төчкерәнә башлау, бертуктаусыз төчкер(ен)ә башлау.

**РАСЧИХВО'СТИТЬ** *сов. простореч. фам.* — кирәген бирү, тар-мар итү, тузлырып бетерү; тетмәсен тетү, тетеп ташлау, измәсен изү.

**РАСЧИЩА'ТЬ** *несов.* — к. расчистить.

**РАСЧИЩА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. расчиститься; 2. *страд.* чистартылу, тазартылу; (чүп-чардан) арчылу, арындырылу.

**РАСЧИ'ЩЕННЫЙ** — чистартылган, арчылган.

**РАСЧЛЕНЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — 1. к. расчленить, расчленяться; 2. буынланыш, бүленеш, бүлгәләнеш; буын, бүлем, бүлемтек.

**РАСЧЛЕНИ'ТЬ** *сов. книж.* — 1. бүлгәләү, бүлгәләп бетерү; төзүче өлешләргә бүлү, кисәкләргә аеру, бүлеп чыгу; 2. бүлеп карау, бүлгәләп ачыклау; *расчленить вопрос* мәсьәләне өлешләргә бүлеп карау.

**РАСЧЛЕНЯ'ТЬ** *несов. книж.* — к. расчленить.

**РАСЧЛЕНЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — бүленү, бүлгәләнү; төзүче өлешләргә аерылу, таркатылу.

**РАСЧУ'ВСТВОВАТЬСЯ** *сов. разг.* — күңел тулу, күңел йомшару, күңел нечкәреп китү; бик нык тәэсирләнү, әсәрләнү, хискә бирелү; *я расчувствовался и заплакал* — күңелем тулды да елап җибәрдем.

**РАСЧУ'ХАТЬ** *сов. простореч. фам.* — 1. иснәп белү, татып белү; 2. *перен.* белү, сизеп алу, аңлап алу, төшенү.

**РАСЧУ'ХАТЬСЯ** *сов. обл. простореч. фам.* — аңышып алу, исенә килү; аңлап (төшенеп) алу.

**РАСШАЛИ'ТЬСЯ** *сов.* — бик нык шаярга башлау, шаярып киту.

**РАСША'РКАТЬСЯ** *сов.* — 1. (бер аякны икенче аякка китереп, үкчәләрне бәреп) баш ию, сәлам бирү, исәнләшү яки хушлашу; 2. *перен., чаще несов., разг. пренебр.* ялагайлык күрсәтү, тәлинкә тоту, куштанланып йөрү; тез чүгү; ...тирәсендә бөтерелеп йөрү, бөгелә-сыгыла йөрү; *расшаркаться перед начальством* — начальниклар алдында бөтерелеп йөрү, начальникларга тәлинкә тоту.

**РАСША'РКИВАТЬСЯ** *несов.* — к. расшаркаться.

**РАСША'ТАННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— какшаганлык, бозылганлык, какшаган булу; *расшатанность здоровья* — сәламәтлекнең какшаганлыгы.

**РАСША'ТАННЫЙ** — 1. какшап беткән, какшаган; 2. *перен.* бозылган, эштән чыккан, рәте киткән, какшаган, загыйфь; *расшатанное здоровье* — какшаган сәламәтлек.

**РАСШАТА'ТЬ** *сов.*— 1. селкетү, какшату; *расшатать гвоздь* — кадакны какшату; 2. *перен. книж.* (нигезен) какшату, йомшарту; бозу; загыйфьләү; *расшатать нервы* — нервларны бозу; *расшатать дисциплину* — дисциплинаны какшату.

**РАСШАТА'ТЬСЯ** *сов.*— 1. какшау, какшап бетү, селкенү; *зуб расшатался* — теш селкенә; 2. *перен.* какшау; рәте китү, бозылу; *дисциплина расшаталась* — дисциплина какшаган.

**РАСША'ТЫВАТЬ** *несов.* — к. расшатать.

**РАСША'ТЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. расшататься; 2. *страд.* какшатылу, селкетелү; какшатып (бозып) бетерелү.

**РАСШВЫ'РИВАТЬ** *несов. разг.*— к. расшвырять.

**РАСШВЫ'РИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — (төрле якка) ыргытылу, ыргытып бетерелү, ташлап бетерелү; төрле якка туздырып (актарылып) ташлану.

**РАСШВЫРЯ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. төрле якка ыргыту, ыргытып бетерү, ыргыткалап бетерү, атып-атып ташлау; төрле якка тондырып бетерү, ташлап бетерү; 2. туздырып (актарып) ташлау, таратып-чәчеп ташлау.

**РАСШЕВЕ'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. расшевелить.

**РАСШЕВЕ'ЛИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. расшевелиться; 2. *страд.* кузгатылу, кузгатып җибәрелү.

**РАСШЕВЕЛИ'ТЬ** *сов.* — 1. (урыныннан) кузгату, селкетү, кыймылдату, кузгатып җибәрү, кузгатып кую; 2. актару, айкау; туздырып (айкап) бетерү; *расшевелить муравейник* — кырмыска оясын айкау; 3. *перен.* хәрәкәткә китерү, кузгату; *его расшевелить трудно* — аны урыныннан кузгату авыр.

**РАСШЕВЕЛИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. кузгалу, селкенә башлау, кыймылдый башлау; 2. *перен. разг.* кузгалу, уяну, дәрт керү, дәртләнеп, (җанланып) киту, хәрәкәткә килү; *он расшевелился и принялся за работу* — ул дәртләнеп китеп эшкә керешге.

**РАСШИБА'ТЬ** *несов.* — к. расшибить.

**РАСШИБА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. расшибиться; 2. *страд.* бәреп имгәтелү.

**РАСШИБИ'ТЬ** *сов.* — 1. (ялгыш) бәрү, бәреп имгәтү, бәреп авырттыру, бәреп яралау; *расшиб руку* — бәреп кулын имгәткән; *расшиб голову об дверь* — башын ишеккә бәргән (бәреп ярган); 2. *разг. (разбить)* бәреп вату, төшереп вату, бәреп яру.

**РАСШИБИ'ТЬСЯ** *сов.* — ялгыш бәрелү, (бәрелеп яки егылып) имгәнү, яралану, җәрәхәтләнү. ◇ **Расшибиться в лепёшку** — к. лепёшка.

**РАСШИВА'ТЬ** *несов.* — к. расшить.

**РАСШИВА'ТЬСЯ** *несов.* — к. расшиться.

**РАСШИ'ВКА** *ж. мн.* нет, *спец.* — к. расшить 1, 3.

**РАСШИВНО'Й** — чигүле, чигеп бизәлгән; чигелгән; *расшивной воротник* — чигүле яка.

**РАСШИРЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед.* к. расширить, расшириться; 2. (берәр нәрсәнең) киңрәк өлеше, киңәя барган өлеше, киңәеше; *расширение трубы* — трубаның киңрәк өлеше.

**РАСШИ'РЕННО, РАСШИРИ'ТЕЛЬНО** *нареч. книж.* — артык киңәйтеп, артык ирекле рәвештә (ягъни төп мәгънәсеннән читкә китеп); *расширительно толковать закон нельзя* — законны артык ирекле аңлатырга ярамый.

**РАСШИ'РЕННЫЙ** — 1. киңәй(тел)гән; киң составлы; *расширенное заседание месткома* — месткомның киңәйтелгән утырышы; 2. *книж.* артык киң, артык ирекле (асыл, төп мәгънәсеннән читкә киткән); *расширенное толкование текста* — текстны артык киң итеп аңлату.

**РАСШИРИ'ТЕЛЬ** *м. спец.* — киңәйткеч, киергеч, киереп зурайткыч.

**РАСШИРИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. к. расширенный 2; 2. *спец.* киңәйтә (зурайта, җәя) торган; киңәйткеч, киергеч.

**РАСШИ'РИТЬ** *сов.*— 1. киңәйтү, киңәйтә төшү; *расширить дорогу* — юлны киңәйтү; 2. зурайту, зурайта төшү; *расширить отверстие* — тишемен зурайту; 3. җәелдерү, тармакландыру; *расширить сеть кинофикации* — кино челтәрен җәелдерү; 4. *перен.* киңәйтү, үстерү, күтәрү; *расширить кругозор* — белем дәрәҗәсен күтәрү (аң-белемен үстерү).

**РАСШИ'РИТЬСЯ** *сов.* — 1. киңәю; зураю; *овраг расширился* — чокыр киңәйгән; 2. арту, киңәю, күбәю, тармаклану; *сеть магазинов расширилась* — магазиннар челтәре киңәйде.

**РАСШИРЯ'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— киңәючәнлек, киңәю сәләте, киңәя торган булу.

**РАСШИРЯ'ТЬ** *несов.* — к. расширить.

**РАСШИРЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. расшириться; 2. *страд.* киңәйтелү, иркенәйтелү, зурайтылу, арттырылу, күбәйтелү.

**РАСШИ'ТЫЙ** — 1. сүтелгән, сүтеп ташланган; сүтек; 2. чиккән, чигүле, чигелгән; *расшитая рубашка* — чиккән күлмәк.

**РАСШИ'ТЬ** *сов.* — 1. текәнне сүтү, кисәкләргә аеру; сүтеп ташлау, сүтеп бетерү;

*расшить книгу* — китапны кисәкләргә аеру; 2. *(украсить узорным шитьём)* чигү, бизәкләп чигү; (алтын, көмеш) белән чигү; 3. *тех.* (җөйләрен, ярыкларын) тигезләү, сылау (төзү эшендә).

**РАСШИ'ТЬСЯ** *сов.* — сүтелеп китү, сүтелеп чыгу, сүтелеп бетү; сүтелеп аерылу (таралып бетү); *книга расшилась* — китап сүтелеп таралган.

**РАСШИФРО'ВАННЫЙ** — расшифровка ясалган, укылган, мәгънәсе ачылган.

**РАСШИФРОВА'ТЬ** *сов.* — 1. шифр белән язылганны уку, расшифровкалау, расшифровка ясау; *расшифровать телеграмму* — телеграмманы расшифровкалау (уку); 2. *перен. разг.* укып аңлау, укып аеру; *его почерка не расшифровать* — аның язуын аерырлык түгел; 3. *перен. разг. шутл.* аңлау, аңлату, мәгънәсенә төшенү; *как расшифровать его слова?* — аның сүзләрен ни дип аңларга? 4. *перен. простореч.* сизеп (белеп) алу, серен ачу, фаш итү.

**РАСШИФРО'ВКА** *ж. мн.* нет, *разг.* — 1. к. расшифровать; 2. расшифровка (шифрлар, шартлы билгеләр белән язылган язманы укып мәгънәсен белү).

**РАСШИФРО'ВЩИК** *м. спец.* — расшифровка ясаучы, расшифровкалаучы, шифрлы язуны укучы-белгеч.

**РАСШИФРО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. расшифровать.

**РАСШИФРО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — расшифровка ясалу, укылу, укып мәгънәсе белену.

**РАСШНУРОВА'ТЬ** *сов.* — шнурны чишү, шнурын чишеп алу, бавын чишү (мәсәлән, ботинканың).

**РАСШНУРОВА'ТЬСЯ** *сов.* — шнуры чишелү, чишелеп китү, чишелеп чыгу.

**РАСШНУРО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. расшнуровать.

**РАСШНУРО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. расшнуроваться; 2. *страд.* шнуры (бавы) чишеп алыну, чишеп куелу.

**РАСШУМЕ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — бик каты шаулый башлау, шау-шу кила башлау, шаулаша башлау, чыр-чу килә башлау; *дети расшумелись* — балалар бик шаулаша башладылар (чыр-чу килә башладылар); 2. *перен. неодобр.* тавыш (җәнҗал, гаугa) куптару, кычкырына (кычкырыша) башлау.

**РАСЩЕБЕ'НИВАТЬ** *несов. тех.* — к. расщебенить.

**РАСЩЕБЕ'НИТЬ** *сов. тех.* — (ташны) ваклау, ваклап (ватып) бетерү, вак ташка әйләндерү.

**РАСЩЕБЁНКА** *ж. тех.* — 1. *только ед.* к. расщебенить; 2. *только ед.* вак таш тутыру (мәсәлән, стена арасына); 3. вак таш, вакланган таш (кирпеч).

**РАСЩЕ'ДРИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. расщедриться.

**РАСЩЕ'ДРИТЬСЯ** *сов. разг.* — артык юмартлану, юмартланып китү, юмартлык күрсәтү.

**РАСЩЕ'ЛИНА** *ж.* — 1. *(ущелье)* тарлавык; 2. (агачта) зур ярык.

**РАСЩЕ'ЛИТЬСЯ** *сов. обл.* — ярылу, яргалану, чатнау.

**РАСЩЁЛКАТЬ** *сов. простореч.* — 1. (шарт-шорт) ватып бетерү (мәсәлән, чикләвекне); (черт-черт) ярып бетерү (мәсәлән, көнбагышны); 2. *фам.* кирәген бирү, измәсен изү, тетеп ташлау; *расщелкать отряд противника* — дошман отрядын тетеп ташлау.

**РАСЩЁЛКИВАТЬ** *несов.* — к. расщелкать, расщелкнуть.

**РАСЩЁЛКНУТЬ** *сов.* — тешләп вату, кыстырып вату (мәсәлән, чикләвекне); черт итеп яру (мәсәлән, көнбагышны).

**РАСЩЕМИ'ТЬ** *сов. разг.* — (кысканны) аеру, ачу, җибәрү; *расщемить клещи* — кләшчәне ачу.

**РАСЩЕМЛЯ'ТЬ** *несов. разг.* — к. расщемить.

**РАСЩЕМЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — аерылу, ачылу, җибәрелү.

**РАСЩЕ'П** *м. спец.* — ярык, ярылган, теленгән урын; *перо с расщепом* — ярыклы каләм.

**РАСЩЕПИ'ТЬ** *сов.* — 1. яру, ярып төшерү; телү, телгәләп (яргалап) бетерү; *расщепить дощечку* — тактаны яргалап бетерү; 2. *спец.* телгәләү, аергалау, кисәкләргә аеру; *расщепить волокна* — җепселләрне телгәләү (кисәкләргә аеру); 3. *хим. (разложить)* таркату, состав өлешләргә аеру.

**РАСЩЕПИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. ярылу, яргалану, телгәләнеп бетү; 2. *спец.* телгәләнү, бүлгәләнү, кисәкләргә аерылу; 3. *хим. (разложиться)* таркалу, состав өлешләргә аерылу.

**РАСЩЕПЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. *книж.* к. расщепить, расщепиться; 2. *хим.* таркалыш, состав кисәкләргә аерылу; *расщепление атомов* — атомнарның таркалышы.

**РАСЩЕПЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. расщепить.

**РАСЩЕПЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. расщепиться; 2. *страд.* таркатылу.

**РАСЩИПА'ТЬ** *сов. разг.* — җепселләргә аеру, җепләрен суырып чыгару, суырып бетерү.

**РАСЩИ'ПЫВАТЬ** *несов.* — к. расщипать.

**РАСЩИ'ПЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — (материянең) җепләре суырылу; җепселләргә аерылу.

**РА'ТАЙ** *м. нар.-поэт.* — сукачы, җир сөрүче, игенче.

**РАТА'НИЯ** *ж. биол.* — ратания (тамырында тире иләү матдәсе булган куак үсемлек).

**РАТА'ФИЯ** *ж. мн.* нет, *устар.* — ратафия (эчемлекләрнең бер төре).

**РАТИ'Н** *м. спец.* — ратин (өске киемнәр тегү өчен төксел йон тукыма).

**РАТИФИКА'ЦИЯ** *ж. полит. дипл.* — ратификация, ратификацияләү, раслау (халыкара договорның югары дәүләт власте тарафыннан раслануы).

**РАТИФИЦИ'РОВАТЬ** *сов. и несов. полит. дипл.* — ратификацияләү, раслау.

**РАТИФИЦИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. полит. дипл.* — ратификацияләнү, раслану.

**РА'ТМАН** *м. истор.* — ратман (реформага кадәрге Россиядә — шәһәр идарәсе әгъзасы).

**РА'ТНИК** *м.* — 1. *старин. и ритор.*

сугышчы, солдат; 2. *дореvол.* ратник (дәүләт ополчениесе солдаты).

**РА'ТНЫЙ** *книж. устар. и поэт.*— 1. яудагы, сугыштагы; *ратные подвиги* — сугыштагы батырлыклар; 2. гаскәри; хәрби; *ратный устав* — хәрби устав. ◇ Ратный конь— сугыш аты, гаскәр аты.

**РАТОБО'РЕЦ** *м. торж. устар. поэт.*— сугышчы, яуда катнашучы (сугышта, бәрелештә катнашучы).

**РАТОБО'РСТВО** *ср. торж. устар. поэт.* — сугыш, яу, бәрелеш, көрәш.

**РАТОБО'РСТВОВАТЬ** *несов. торж. устар. поэт.* — сугышу, бәрелештә катнашу, көрәшү.

**РА'ТОВАТЬ** *несов. книж. устар.* — көрәшү, яклау, (берәр нәрсәне) яклап сөйләү; (берәр нәрсәгә) каршы сөйләү; *ратовать за просвещение* — мәгърифәт өчен көрәшү.

**РАТУ'Й(ТЕ)!** *обл. пов. накл.* — коткар (ыгыз)! ярдәм ит(егез)!

**РА'ТУША** *ж.*— ратуша (1. урта гасырдагы немец шәһәрләрендә идарә органы; 2. кайбер илләрдә шәһәр үзидарәсе һәм шул идарә урнашкан бина).

**РАТЬ** *ж. поэт. старин.* — 1. *(войско)* гаскәр, яу; ләшкәр, чирү; 2. сугыш, бәрелеш, яу; *не хвались, идучи на рать* — яуга барганда мактанма.

**РА'УНД** *м. спорт.* — раунд (бокста каракаршы көрәшүчеләрнең бер алышу дәвамы).

**РА'УТ** *м.* — зур (тантаналы) кичә, кабул мәҗлесе.

**РАФИНА'Д** *м. мн.* нет — рафинад, шакмак шикәр (сафландырылган каты ак шикәр).

**РАФИНА'ДНЫЙ** — рафинад (шикәр)...-ы; *рафинадный завод* — рафинад заводы, шикәр заводы.

**РАФИНЁР** *м. тех.* — рафинёр (кәгазь фабрикасында агач массасын тарттыру һәм чистарту машинасы).

**РАФИНЁРНЫЙ** *тех.* — 1. сафландыру (арындыру, чистарту) ...-ы; *рафинёрный цех* — сафландыру цехы; 2. сафландырыла торган, чистартыла торган; *рафинёрная масса* — сафландырыла (чистартыла) торган масса.

**РАФИНЁРЩИК** *м. спец.* — рафинёрчы (кәгазь фабрикасында рафинёр машинасында эшләүче эшче).

**РАФИНИ'РОВАНИЕ** *ср. мн.* нет, *спец.*— 1. рафинад шикәр ясау; 2. сафландыру, кирәксез катнашмалардан арындыру.

**РАФИНИ'РОВАННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — артык нәзакәтлелек, артык нечкәлек (мәсәлән, артык нечкә тамаклы булу, артык нечкә татымлы булу).

**РАФИНИ'РОВАННЫЙ** — 1. *спец.* сафландырылган, чистартылган, арындырылган; 2. *перен. книж.* нечкә; *рафинированный вкус* — нечкә зәвык; 3. *перен. книж. ирон.* чиктән ашкан, утә; *рафинированный негодяй* — чиктән ашкан кабахәт.

**РАФИНИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. тех.* — 1. чистарту, тазарту, сафландыру, арындыру; *рафинировать нефть* — нефтьне арындыру; 2. рафинадка әйләндерү (шикәр комын).

**РАФИНИРО'ВОЧНЫЙ** *тех.* — арындыру ...-ы; *рафинировочная печь* — арындыру миче (кою цехларында).

**РАФИНИРО'ВЩИК** *м. спец.* — рафинировщик (продукцияне кирәксез катнашмалардан арындыручы эшче яки белгеч).

**РАХА'Т-ЛУКУ'М** *м.* — рәхәтлокым (тортсыман ашамлык).

**РАХИ'Т** *м.* — рахит, рахит авыруы, уа авыруы (яшь балалар организмында известь тозларының җитмәве сәбәпле, сөякләрнең вакытында катып ныгымавы һәм зәгыйфь, тигезсез үсүеннән гыйбарәт булган авыру).

**РАХИТИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *мед.* — рахитизм, рахитлык, рахитлык билгеләре.

**РАХИ'ТИК** *м.*, **РАХИТИ'ЧКА** *ж. разг.*— рахит белән авыручы бала, уа булган бала, рахитлы бала.

**РАХИТИ'ЧЕСКИЙ** *мед.* — рахитлы, уалы; рахит авырулы, рахит белән авыручы.

**РАХИТИ'ЧНЫЙ** — 1. к. рахитический; 2. *перен. пренебр. (выродившийся, бездарный)* черек, череп баручы; зәгыйфь, сәләтсез.

**РАЦЕ'Я** *ж. разг. неодобр.* — үгет, үгетнәсихәт.

**РАЦИО'Н** *м.* — рацион, көнлек азык (көнлек азык нормасы).

**РАЦИОНАЛИЗА'ТОР** *м.* — рационализатор, рационаллаштыручы, рационализация кертүче.

**РАЦИОНАЛИЗА'ТОРСКИЙ** — рационаллаштыру...-ы; рационализация...-ы; рационализаторлык...-ы; *рационализаторское предложение* — рационаллаштыру тәкъдиме; *рационализаторский талант* — рационализаторлык таланты.

**РАЦИОНАЛИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — рационаллаштыру, рационализация,камилләштерү.

**РАЦИОНАЛИЗИ'РОВАННЫЙ** — рационаллаштырылган, камилләштерелгән.

**РАЦИОНАЛИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— 1. рационаллаштыру, рационализация ясау, рационализация үткәрү; камилләштерү 2. *филос.* рационалистларча карау (рационализм фәлсәфәсе күзлегеннән карау).

**РАЦИОНАЛИЗИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.*— рационаллаштырылу, камилләштерелү; рационализация үткәрелү.

**РАЦИОНАЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.* — рационализм (1. *филос.* идеалистик философиядә — дөньяны танып-белүдә төп чыганак тәҗрибә түгел, бәлки гакыл һәм гакыл эше дип хисаплаучы юнәлеш; 2. *перен. книж.* акыл белән эш итү).

**РАЦИОНАЛИЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.* — к. рационализировать.

**РАЦИОНАЛИЗОВА'ТЬСЯ** *несов.* — к. рационализироваться.

**РАЦИОНАЛИ'СТ** *м. книж.* — рационалист, рационализм тарафдары.

**РАЦИОНАЛИСТИ'ЧЕСКИЙ** *книж.* — 1. рационализм...-ы; *рационалистические системы* — рационализм системалары; 2. гакылга нигезләнгән, акылга муафыйк; *ра-*

*ционалистический поступок* — акылга муафыйк эш.

**РАЦИОНАЛИСТИ'ЧНЫЙ** *книж.* — к. рациональный 2.

**РАЦИОНАЛИ'СТКА** *ж. книж.* — к. рационалист.

**РАЦИОНА'ЛЬНО** *нареч.* — рациональ рәвештә; *рационально использовать* —рациональ рәвештә файдалану.

**РАЦИОНА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — рациональлек, рациональ булу(чылык); акылга муафыйклык.

**РАЦИОНА'ЛЬНЫЙ** *книж.* — 1. *книж.* рационализм...-ы; *рациональная философия* — рационализм философиясе; 2. рациональ; акыллы, акылга муафыйк, акылга ятышлы; төпле, нигезле; *рациональное использование рабочего времени* — эш вакытын рациональ файдалану; 3. *мат.* рациональ; *рациональные числа* — рациональ саннар (барлык бөтен саннар, гади вакланма белән күрсәтеп була торган саннар һәм нуль). ◇ **Рациональное зерно** *чего-н. книж.* — рациональ бөртек (берәр әсәрнең, хезмәтнең, тәгълиматның әһәмияткә лаек һәм файдалы өлеше).

**РА'ЦИЯ** *ж. спец.* — рация, радиостанция.

**РА'ЧИЙ** — кысла...-ы; кысланыкы төсле; *рачьи глаза* — кысланыкы төсле (акайган) күзләр.

**РАЧИ'ТЕЛЬ** *м. книж. устар.* — кайгыртучы, тырышучы; хәстәрлек күрсәтүче, караучы; саклаучы, сакчы.

**РАЧИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж. устар.* — тырышлык, кайгыртучанлык, күңел бирүчәнлек.

**РАЧИ'ТЕЛЬНО** *нареч.* — тырышып, күңел биреп.

**РАЧИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж. устар.* — тырыш, тырышучан, иҗтиһатлы, күңел бирүчән, күңел куеп эшләүчән; кайгыртучан; хәстәрлекле, сакчыл.

**РАЧИ'ХА** *ж. разг.* — ана кысла.

**РАЧИ'ШКА** *ж. разг. пренебр.* — кечкенә кысла, кысла кисәге.

**РАЧНО'Й** *обл.* — кыслага бай; кыслалы; *рачное озеро* — кыслага бай күл.

**РА'ШКУЛЬ** *м. живоп.* — күмер карандаш (рәсем ясау өчен).

**РА'ШПИЛЬ** *м. тех.* — рашпиль, эре сырлы игәү.

**РАЩЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — үстерү.

**РВАНУ'ТЬ** *сов.* — 1. *просторечн.* тарту, йолку, йолкып алу; тартып җибәрү, тартып куюҗ *рвануть волосы* — чәчләрен йолкып алу; *рванул меня за рукав* — җиңемнән тартып куйды; 2. *разг.* кинәт кузгалу, кузгалып китү, тартып (ыргып) алып китү; *тройка рванула и понесла* — тройка кинәт кузгалып, чаптырып алып китте; 3. *просторечн. фам.* эләктерү, чумырып алу, үзләштерү; *рванул изрядный куш* — шактый зур сумма (акча) эләктергән.

**РВАНУ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — кинәт кузгалу, ыргылу, ургылу, тартылу; чабып китү; сикереп... тору, атылып... тору; *мальчик рванулся с места и выбежал вон (Чехов)* — малай атылып урыныннан торды да, йөгереп чыгып китте; *лошади рванулись вперёд* — атлар кинәт алга ыргылдылар (чабып киттеләр).

**РВА'НЫЙ** — ертык, ертылган, тишек-тошык, сәләмә; ертылып (тетелеп) беткән, өзелеп төшкән; *рваные брюки* — ертык чалбар. ◇ **Рваная рана** *мед.* — ертылулы җәрәхәт (кырыйлары тигез булмаган яра). **Рваная ноздря** *старин.* — ерык борын (әүвәл заманнарда борын яфрагын ертып җәзаланган җинаятьче).

**РВАНЬ** *ж. мн.* нет — 1. *разг. фам.* искемоскы, ертык-портык, сәләмә, ертык кием; 2. *собир. тех.* калдык-постык җепләр, кыйпык-кисек, кисәк-косак, чүпрәк-чапрак; 3. *ед. и собир. перен. презр. бран.* әшәке кеше, юньсез кеше, кабахәт.

**РВАНЬЁ** *ср. мн.* нет — 1. к. рвать I, 1.; 2. *собир. разг. фам. (рваная одежда, обувь)* ертык-портык кием; сәләмә, иске-москы.

**РВАТЬ** I *несов.* — 1. суыру, суырып чыгару (алу); тарту, тартып алу; *рвать гвозди* — кадак суыру; *не рви из рук* — кулдан тартып алма; 2. (төбе-тамыры белән) кубару; куптарып чыгару, куптарып ыргыту; *буря с корнем рвёт деревья* — давыл агачларны төбе-тамыры белән куптарып ыргыта; 3. өзү; *машина рвёт нитку* — машина җепне өзә; 4. өзеп (сындырып) алу; йолку, җыю; *рвать цветы* — чәчәк өзеп алу; *рвать ягоды* — җиләк җыю; *рвать траву* — чирәм йолку; 5. ерту, ерткалау; умыру; *рвать платье* — күлмәкне ерту; 6. *спец.* кискен хәрәкәтләр ясау; *рвать при гребле* — кискен хәрәкәтләр ясап ишү; 7. шартлату; актарту; *рвать динамитом скалу* — кыяны динамит белән шартлату; 8. *перен.* өзү, туктату, бетерү; *рвать отношения* — мөнәсәбәтләрне өзү; 8. *безл.* сулкылдау, сулкылдап авырту, сызлау; *нарыв сильно рвёт* — шеш бик нык сызлый. ◇ **Рвать на себе волосы** — чәчләрен йолку (нишләргә белмичә). **Рвать на части** — к. разорвать на части. **Рвать и метать** *разг.* — пыр туз(дыр)у, буран туздыру (бик нык ачулану). **Рвать зубы** *разг.* — теш ал(дыр)у, теш суыр(т)у.

**РВАТЬ** II *несов. безл. разг.* — косу, костыру, косасы килү, укшыту, күңел болгану.

**РВА'ТЬСЯ** I *несов.* — 1. *страд. (выдёргиваться)* суырылу, суырып чыгарылу, тартып алыну; кубарылу, куптарып ыргытылу (төбе-тамыры белән); 2. *страд. (о цветах, ягодах)* җыелу, өзеп (сындырып, йолкып) алыну; 3. өзелү, ертылу, тузу; умырылу; *обувь рвётся* — аяк киеме ертыла (туза); *верёвка рвётся* — бау өзелә; 4. шартлау, шартлап ярылу; *снаряды рвутся* — снарядлар шартлый (ярыла); 5. *страд. (об отношениях)* өзелү, туктатылу, бетерелү; 6. *перен. (о сердце)* өзгәләнү, үзәк өзелү; йөрәге теленү. ◇ **Где тонко, там и рвётся** — һәр нәрсә нечкә җиреннән өзелә.

**РВА'ТЬСЯ** II *несов.* — омтылу, атлыгу; ыргылу, тартылу; атылып (ыргылып) тору; ашкыну; талпыну; *войска рвутся вперёд* — гаскәрләр алга омтыла; *душа рвётся* — күңел ашкына; *ребёнок рвался к матери* — бала анасына барырга атлыгып тора иде.

**РВАЧ** *м. разг.* — рвач, ертлач; комсыз (һәрнәрсәдән үзенә файда чыгарырга гына торучы кеше).

**РВА'ЧЕСКИЙ** *разг.* — рвачлык (ертлачлык)...-ы; рвачларча..; *рваческие наклонности* — рвачлык гадәтләре.

**РВА'ЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *разг.* — рвачлык, комсызлык, ертлачлык.

**РВЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — гайрәт, тырышлык, күңел бирү, күңел салу; атлыгу, ашкыну, омтылу; *работать с необыкновенным рвением* — гаять зур тырышлык белән эшләү.

**РВО'ТА** *ж. мн.* нет — 1. косу, костыру; 2. *разг.* косык. ◇ **Позыв к рвоте** — укшу, косасы килү. **Клонить к рвоте** — укшыту, косасыны китерү.

**РВО'ТНОЕ** *ср. в знач. сущ. мед.* — костыру дарусы, костыра торган дару; *дать рвотного при отравлении* — агуланган чакта костыру даруы бирү.

**РВО'ТНЫЙ** — 1. *мед.* косу...-ы; *рвотные явления* — косу күренешләре; 2. костыра торган, костыру...-ы; *рвотные средства* — костыру чаралары (дарулары).

**РДЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — к. рдеть.

**РДЕТЬ** *несов. книж.* — кызару, алсулану, кып-кызыл булу, алсуланып яну, алсуланып тору, кызарып тору.

**РДЕ'ТЬСЯ** *несов.* — к. рдеть.

**РДЯ'НЫЙ** *устар. поэт.* — кып-кызыл, ал, алсу.

**РЕ** *ср. нескл. муз.* — ре, ре нотасы, ре тавышы (музыка гаммасында икенче тавыш).

**РЕАБИЛИТА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. аклану; саф исемен (абруен) кире кайтару; *он добился полной реабилитации* — ул тулысынча аклануга иреште; 2. *право* хокукларын кире кайтару, аклау, реабилитация(ләү).

**РЕАБИЛИТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.* — аклау, реабилитацияләү, элекке хокукын (тапланмаган исемен) кире кайтару.

**РЕАБИЛИТИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. книж.* — аклану, реабилитацияләнү, элекке хокуклары кайтарылу.

**РЕАГЕ'НТ** *м. хим.* — к. реактив.

**РЕАГИ'РОВАТЬ** *несов.* — 1. *хим.* химик реакциягә керү, химик реакциягә катнашу; 2. *книж.* сизү, тою; реакция ясау, тәэсирләнү, тынычсызлану; (тышкы тәэсиргә) җавап кайтару; *зрительный нерв реагирует на свет* — күрү нервы яктылыкны сизә; 3. *перен.* карау, мөнәсәбәтен күрсәтү; каршы җавап бирү, әйтү; эш итү; *не знал как реагировать на его слова* — аның сүзләренә ничек җавап бирергә дә белмәдем.

**РЕАКТИ'В** *м. хим.* — реактив (берәр составка кушылгач, билгеле бер химик реакция ясалуга сәбәп була торган һәм шуның белән әлеге состав эчендә эзләнмә матдәнең бармы-юкмы икәнлеген билгеләргә мөмкинлек бирә торган матдә).

**РЕАКТИВИ'СТ** *м. спец.* — реактивлар кәзерләүче (лаборант).

**РЕАКТИ'ВНОСТЬ** *ж. мн*, нет, *хим.* — реактивлык, реактив булу, реакция бирүчәнлек, реакция ясау сәләте.

**РЕАКТИ'ВНЫЙ** *хим. физ.* — 1. *хим.* реактив, химик реактив буларак кулланыла торган; *реактивные вещества* — реактив матдәләр; 2. *физ. тех.* реактив (атылып чыга торган газлар тәэсирендә хәрәкәт итүче); *реактивный самолёт* — реактив самолёт.

**РЕАКТОЛО'ГИЯ** *ж. устар. псих.* — реактология (кешенең хәрәкәтләре аның тышкы тәэсирләргә җавап реакцияләре ул, дигән тәгълимат).

**РЕА'КТОР** *м. тех.* — реактор.

**РЕАКЦИОНЕ'Р** *м.*, **РЕАКЦИОНЕ'РКА** *ж* — реакционер (реакцион политика яклы кеше; искелекне аклаучы, прогресска каршы кеше, прогресс дошманы; кадимче).

**РЕАКЦИО'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет — реакционлык.

**РЕАКЦИО'ННЫЙ** — 1. реакцион; *реакционная печать* — реакцион матбугат (кадимчеләр матбугаты); 2. *хим. физ.* реакция..-ы; *реакционная камера* — реакция камерасы (химик реакция ясала торган камера).

**РЕА'КЦИЯ** I *ж. полит.* — реакция (революцион хәрәкәткә һәм һәртөрле прогресска каршы көрәшү юлы белән иске тәртипләрне кире кайтарырга яки саклап калырга тырышу политикасы; шундый политиканы тотучы дәүләт режимы).

**РЕА'КЦИЯ** II *ж. книж.* — 1. реакция, каршы хәрәкәт, каршы җавап; кире тәэсир, каршылык; *грубость обращения всегда вызывает соответствующую реакцию* — мөгамәләдә тупаслык һәрвакыт үзенә карата тиешле реакция тудыра; 2. *науч.* сизү, тәэсирләнү, тынычсызлану; реакция; *реакция организма на холод* — организмның суыкка реакциясе (суыктан тынычсызлануы); 3. *только ед.* рух төшү, төшенкелек, хәлсезлек (берәр рухи халәттән кинәт капмакаршы халәткә күчү); 4. *хим.* реакция (матдәләрнең үзара тәэсир итешүе яки энергия тәэсире сәбәпле таркалу, үзгәрү һәм әверелү процессы).

**РЕАЛ** *м. тип.* — реал (типографиядә хәрефләр һәм гранкалар салып куюөчен бүлемтекле шкаф).

**РЕАЛИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, — к. реализовать, реализоваться.

**РЕАЛИ'ЗМ** I *м.* — 1. *лит. искус.* реализм (әдәбиятта һәм сәнгатьтә — тормышны, чынбарлыкны типиклаштырган хәлдә тулы һәм дөрес чагылдыруны максат итеп куйган юнәлеш); **социалистический реализм** — социалистик реализм (реализмның яңа, иң югары үсеш баскычы, совет сәнгате, матур әдәбияты һәм тәнкыйтенең төп методы; ул язучыдан чынбарлыкны революцион үсештә дөрес һәм тарихи конкрет сурәтләүне, хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләүгә юнәлдерелгән әсәрләр иҗат итүне таләп итә). 2. тормышчанлык, реальлек, реаль мөмкинлекләрне хисапка алу, тормышка аек карау, тормыш шартларын исәпкә алып эш итү.

**РЕАЛИ'ЗМ** II *м. филос.* — реализм (1. XIX—XX йөзләрдә кайбер корама фәлсәфи системаларның атамасы; 2. урта гасырларда — гомуми төшенчәләр әйберләргә

кадәр булалар һәм алардан бәйсез рәвештә реаль яшиләр, дигән схоластик, фәлсәфи тәгълимат). ◇ **Наивный реализм** *филос.* — садә реализм (тышкы дөнья турында кешенең тойгылары биргән тәэсирләр белән реаль чынбарлыкның үзен бер үк дип караучы философик тәгълимат).

**РЕАЛИЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. книж.*— 1. (*осуществить*) эшкә ашыру, гамәлгә ашыру, тормышка ашыру; эшләп (үтәп) чыгу, үтәү; реальләштерү; 2. (*продать*) сату, акчага әйләндерү, реализацияләү; 3. (*о займах*) урнаштыру, тарату.

**РЕАЛИЗОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов. книж.*— 1. (*осуществиться*) тормышка ашу, гамәлгә ашу, эшкә ашу; 2. *спец.* (*о ценностях*) сатылу, сатылып бетү; акчага әйләнү, реализацияләнү; 3. *страд.* эшкә (тормышка) ашырылу.

**РЕАЛИ'СТ** I *м.*— реалист (1. сәнгатьтә һәм әдәбиятта реализм тарафдары, реалист язучы; 2. *филос.* реализм тарафдары; 3. *перен.* тормышка аек караучы, практик яктан караучы; реаль тормыш шартларын (практик мөмкинлекләрне) исәпкә алып эш итә торган кеше).

**РЕАЛИ'СТ** II *м. дореволюц.* — реалист (элекке Россиядә реальный училище укучысы).

**РЕАЛИСТИ'ЧЕСКИЙ** *книж.*—1. реалист...; *реалистический писатель* — реалист язучы; 2. реалистик; *реалистический роман* — реалистик роман; 3. реаль, аек, практик, аек күз белән...; *реалистическое отношение к жизни* — тормышка аек күз белән (реаль) карау.

**РЕАЛИСТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— к. реальность 1.

**РЕАЛИСТИ'ЧНЫЙ**—к. реалистический 3.

**РЕАЛИ'СТКА** *ж.*— к. реалист I.

**РЕА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— 1. реальлек, реаль булу, чын (тормышчан) булу; *реальность программы* — программаның реаль булуы; 2. реаль чынбарлык, чынлык, факт; *это не мечта, а реальность* — бу хыял түгел, бәлки реаль чынбарлык.

**РЕА'ЛЬНЫЙ** — 1. реаль, чынбарлыкта булган, чын, чын булган; *реальная жизнь* — реаль тормыш; 2. гамәлгә (эшкә, тормышка) ашырлык; реаль; *реальный план* — тормышка ашырлык план; 3. аек, практик; реаль шартларны исәпкә алган; реаль, тормышчан; *реальный взгляд на жизнь* — тормышка аек күз белән карау; *реальная политика* — реаль политика; 4. *устар.* реаль, практик, тормышта кулланыла торган; *реальные науки* — реаль (практик) фәннәр. ◇ **Реальное училище** *дореволюц.*— реальное училище (борынгы телләр укытылмыйча, күбрәк математика һәм табигать фәннәре укытыла торган урта уку йорты). **Реальная заработная плата** — реаль эш хакы (эш хакының сатып алу сәләте).

**РЕБЁНОК** *м.*— 1. бала; яшь бала, нәни бала; сабый, сабый бала; *помилуйте, мы с вами не ребята* (*Грибоедов*) — гафу итегез, сезнең белән без сабый балалар түгел инде; *грудной ребёнок* — имчәк баласы (бәби); 2. *перен.* беркатлы кеше, сабый бала; *он настоящий ребёнок* — ул бөтенләй сабый бала кебек (уйламыйча эш итүе белән балалардан аермасы юк).

**РЁБЕРНЫЙ** *анат.*— кабырга...-ы; *рёберные мышцы* — кабырга мускуллары.

**РЕБО'РДА** *ж. тех.* — реборда (вагон тәгәрмәченең рельстан төшүен саклый торган чыгынтылы кырые).

**РЕБРИ'СТЫЙ** и **РЁБРИСТЫЙ** — 1. кабыргалары чыккан, калку кабыргалы, кабыргалары беленеп торган (ябык); 2. кырлы, сырлы, кырлы-кырлы; *рёбристая труба* — кырлы-кырлы труба.

**РЕБРО'** *ср.*— 1. *анат.* кабырга; 2. *мат.* кабырга (ике яссылыкның кисешү сызыгы); 3. кыр, кырый, ян; *поставить кирпич ребром* — кирпечне яны белән кую; *положить доску ребром* — тактаны кыры белән кую. ◇ **Поставить ребром** (последнюю копейку) *разг.*— (акчаны) тотып бетерү; (карта уенында) тәвәккәлләү. **Поставить ребром** (вопрос) — (мәсьәләне) кабыргасы белән кую, кискен (катгый) кую. **Пересчитать рёбра** — кабыргаларын санау, кыйнау.

**РЕ'БУС** *м.*— 1. ребус (хәрефләр урынына төрле билгеләр, рәсемнәр куелып „язылган" табышмаклы мәкаль, әйтем, шигырь өзеге һ. б. ш.); 2. *перен.* чуалчык мәсьәлә, табышмак, аңлаешсыз нәрсә.

**РЕБЯ'ТА** — 1. балалар, бала-чага; 2. *собир. разг.* егетләр, яшьләр; (*товарищи по учёбе, работе*) малайлар, кызлар, иптәшләр (классташлар һ. б.).

**РЕБЯТИ'ШКИ** *ед.* нет, *простореч. фам.*— кечкенә (нәни, яшь) балалар; (берсеннән-берсе) вак балалар, бала-чага.

**РЕБЯ'ТУШКИ** *ед.* нет, *простореч. фам.*— балакайлар.

**РЕБЯ'ЧЕСКИЙ** *разг.* —1. (яшь) бала...-ы; сабый бала...-ы; балалар...-ы; *ребяческий крик* — сабый бала тавышы; 2. балалык...-ы; балаларча..., җиңел, уйламыйча эшләнгән; *ребяческие выходки* — балалык кыланышлары.

**РЕБЯ'ЧЕСТВО** *ср. мн.* нет — 1. балачак, бала вакыт, сабыйлык вакыты; *я всё ребячество провёл в одиночестве* — мин балачагымны ялгызлыкта үткәрдем; 2. *перен.* (*легкомысленное поведение*) балалык, малайлык, балаларча җиңел уйлау, балаларча беркатлылык.

**РЕБЯ'ЧИЙ** *разг. фам.*: **ребячьи игрушки** — бала уенчыклары.

**РЕБЯ'ЧИТЬСЯ** *несов. разг.*— балалану, бәбәйләнү, балаларча кылану, шуклану, шаяру.

**РЕБЯ'ЧЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.*— баласымаклык, балаларча кыланыш.

**РЕБЯ'ЧЛИВЫЙ** *разг.*— баласымак; балаларча; шук, шаян; үзен балаларча тотучы; *ребячливый нрав* — баласымак гадәтле.

**РЁВ** *м. мн.* нет — 1. үкерү, акыру, улау; *звери подняли рёв* — җанварлар үкерә (үкерешә) башладылар; 2. *перен.* (*беспорядочные крики*) чыр-чу, акырыш-бакырыш, кычкырыш; 3. *перен.* ыжгыру, улау, гүләү;

гүелдәү; *рёв ветра* — җил улавы (ыжгыруы); 4. *перен.* гөр, гөрләү, гөрелдәү, күкрәү, гөрселдәү; *рёв моторов* — моторлар гөрләве; *рёв пушек* — туплар гөрселдәве; 5. *разг.* (*громкий плач*) акырып елау, үкереп елау.

**РЁВА** *м.* и *ж. простореч., фам. презрит.*— елак бала, көйсез бала.

**РЕВАКЦИНА'ЦИЯ** *ж. мед.*— ревакцинация (икенче кат прививка ясау).

**РЕВА'НШ** *м.* — реванш (сугышта яки уенда җиңелгән якның үч кайтару теләге белән сугышны янсә уенны кабатлавы).

**РЕВАНШИРОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.*— реванш алу, үч кайтару.

**РЕВАНШИ'СТ** *м. книж.*— реваншчы, реванш алырга омтылучы, реванш политикасын тотучы; *фашистские реваншисты* — фашист реваншчылары.

**РЕВАНШИ'СТСКИЙ** *книж.*—реванш...-ы; реваншчы...-ы; реваншчылык...-ы; реваншистларча..., реваншка нигезләнгән: *реваншистская политика* —реванш политикасы; *реваншистские настроения* — реваншчылык настроениеләре.

**РЕВА'НШНЫЙ** —реванш...-ы; реванш алу өчен...; *реваншная схватка* — реванш алу өчен көрәшү.

**РЕВВОЕНСОВЕ'Т** (революционный военной совет) *м.*— реввоенсовет (революцион хәрби совет).

**РЕВЕ'НЬ** *м.*— ревень (1. *бот.* дару үләне; 2. *мед.* шул үләннең тамырыннан ясала торган эч йомшарткыч дару).

**РЕВЕРА'НС** *м.*— 1. реверанс (тез чүгеп исәнләшү формасы); 2. *перен. шутл.* (*расшаркивание*) бөгелә-сыгыла сәлам бирү, артык хөрмәт (тәкәллеф) күрсәтү.

**РЕ'ВЕРС** *м.*— реверс (1. *спец.* акчаның иләк ягы; 2. *экон. торг.* гарантия язуы, йөкләмә язуы; 3. *тех.* машинаның хәрәкәт юнәлешен кире якка үзгәртүче механизм).

**РЕВЕ'РСЕР** *м. тех.* — реверсер (мотор валларының әйләнешен үзгәртү өчен өзгеч).

**РЕВЕРСИ'ВНЫЙ** *тех.*— реверсив (әйләнү хәрәкәт юнәлеше үзгәртелә торган); *реверсивный мотор* — реверсив мотор.

**РЕВЕ'РСИЯ** *ж. мн.* нет — реверсия (1. *право* милекне элекке иясенә кайтару; 2. *тех.* машинаның әйләнү юнәлешен үзгәртү; 3. *биол.* борынгы бабалар формасына кире кайту күренеше, атавизм).

**РЕВЕ'ТЬ** *несов.*— 1. үкерү, акыру, бакыру; үкерешү, акырышу, бакырышу; *ревёт медведь* — аю акыра; *ревут быки* — үгезләр үкерешә; 2. шаулашу, гөж килү, шау-шу килү; *толпа ревела в восторге* — халык шатлыктан гөж килә иде; 3. *перен. разг. пренебр.* каты кычкыру, акыру, бакыру, акырып сөйләү. акырып-бакырып җырлау, бугаз кирү; (*о мно их*) шаулашу, кычкырышу, акырышу-бакырышу; *что ты ревёшь под самым ухом?* — нәрсә син, минем колак төбенә үк килеп акырасың? 4. *перен.* шаулау, улау, ыжгыру, гөрелдәү, гүләү; *буря ревёт* — давыл улый; 5. *простореч.* үкереп елау, кычкырып елау, акырып-бакырып елау; *ребята ревмя ревут* — балалар үкереп-үкереп елыйлар.

**РЕВИЗИОНИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *филос.*— ревизионизм (1. марксизмга ревизия ясауны, ягъни марксизм тәгълиматының нигезләрен тәнкыйтьләп һәм инкарь итеп, аларны гыйльми-революцион булмаган теорияләр белән алмаштыруны таләп итеп чыккан реакцион агым — халыкара оппортунизмның бер төре; 2. гомумән — берәр теорияне, тәгълиматны һ. б. янадан карап тәнкыйть итү).

**РЕВИЗИОНИ'СТ** *м. полит.* — ревизионист, ревизионизм тарафдары, ревизионизмны яклаучы.

**РЕВИЗИОНИ'СТСКИЙ** *полит.*—ревизионизм...-ы; ревизионистлык...-ы; ревизионизмга нигезләнгән; *ревизионистская политика* — ревизионизм политикасы.

**РЕВИЗИО'ННЫЙ** — ревизия...-ы; тикшерү...-ы; *ревизионная комиссия* — ревизия комиссиясе (эшне, исәп-хисапны тикшерү комиссиясе).

**РЕВИ'ЗИЯ** *ж.*— 1. ревизия, тикшерү; *ревизия кассовой отчётности* — кассаның исәп-хисабын тикшерү; 2. *книж.* ревизия, ревизияләү, ревизия ясау (берәр тәгълиматның нигезен боза торган үзгәртүләр кертү максаты белән, аның төп куелышларын яңадан карау); 3. *истор.* ревиз, сан алу (18—19 гасырларда Россиядә салым салу өчен халык санын исәпкә алу); 4. *разг. шутл.* тикшереп (актарып) карау, ревизия ясау, эзләү.

**РЕВИЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.*— 1. ревизия ясау, ревизияләү, ревизия үткәрү; тикшерү, тикшереп чыгу; 2. *книж.* ревизияләү, ревизия ясау, яңадан карау (берәр тәгълиматның нигезләрен тәнкыйть һәм инкарь итү); *попытки ревизовать революционное учение Маркса были разоблачены Лениным* — Маркснын революцион тәгълиматына ревизия ясау омтылышлары Ленин тарафыннан фаш ителде.

**РЕВИЗО'Р** *м.* — ревизор, ревизияләүче; тикшерүче.

**РЕВИЗО'РСКИЙ** — ревизорлык (ревизия ясау)...-ы; тикшерү...-ы; *ревизорские обязанности* — ревизорлык бурычлары.

**РЕВИ'ЗСКИЙ** *истор.*: **ревизская сказка** — ревиз исемлеге (ясак түләүчеләр исемлеге); **ревизская душа** — ревиз исемлегенә кергән кеше (ясак салынган кеше).

**РЕВКО'М** (*революционный комитет*) *м.*— ревком (революцион комитет).

**РЕВМАТИ'ЗМ** *м.*— ревматизм, ревматиз авыруы (буыннарда һәм мускулларда була торган коры сызлау авыруы).

**РЕВМА'ТИК** *м.*, **РЕВМАТИ'ЧКА** *ж. мед.*— ревматик, ревматизм авырулы кеше, буыннары сызлаулы кеше.

**РЕВМЯ'** *нареч.*: **ревмя реветь** (*разг.*)— акырып елау, үкереп-үкереп елау.

**РЕВНИ'ВЕЦ** *м.*, **РЕВНИ'ВИЦА** *ж. разг. устар.*— көнче кеше, көнлә(ш)үче кеше, көнләшүчән кеше, көнчелек итүче.

**РЕВНИ'ВО** *нареч.*— 1. көнлә(ше)п, көнләшү (көнчелек) белән, кызыгып; *ревниво*

*посмотреть на кого-н.* — берәүгә көнләшеп карау; 2. бик тырышып; *ревниво оберегать свою работу* — үз эшен бик тырышып саклау.

**РЕВНИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — көнчелек, көнләшүчәнлек.

**РЕВНИ'ВЫЙ** — 1. көнче, көнләшүчән, көнләүчән; *ревнивый муж* — көнләүчән ир; 2. көнләшүчән, көнчелекле, көнләшүле; *ревнивый взгляд* — көнләшүле караш.

**РЕВНИ'ТЕЛЬ** *м.*, **РЕВНИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж. книж. устар.* — тырышучы; тырышып (ихлас белән) эшләүче; фидакарь көрәшүче, тырышып яклаучы; *ревнитель просвещения* — мәгърифәт өчен тырышучы.

**РЕВНОВА'ТЬ** *несов.* — 1. көнләү, көнләшү; *жена мужа ревнует* — хатыны ирен көнли; 2. *устар.* көнчелек килү, көнләшү, кызыгу; *ревновать славе друга* — дустының даныннан көнләшү; 3. *устар.* берәр эш өчен тырышу, кайгырту, яну, көю; тырышып йөрү; *ревновать о благе отечества* — ватан файдасы (мәнфәгате) турында кайгырту.

**РЕ'ВНОСТНО** *нареч.* — тырышып, жантән белән, фидакарь (рәвештә), янып-көеп, бирелеп, ихлас белән.

**РЕ'ВНОСТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — тырышлык, иҗтиһат; *он проявлял большую ревностность в учении* — ул укуда зур тырышлык күрсәтә иде.

**РЕ'ВНОСТНЫЙ** *книж.* — бик тырыш, ихласлы; *ревностный работник* — бик тырыш эшче (янып-көеп эшләүче).

**РЕ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. көнләү, көнләшү, көнләшүчәнлек, көнчелек; *муки ревности* — көнчелек газаплары; 2. *книж. устар.* (*усердие, рвение*) тырышу, тырышлык, ашкыну; гайрәт.

**РЕВОКА'ЦИЯ** *ж.* — 1. *торг.* ревокация, юкка чыгару (элек бирелгән боерыкны); 2. *торг.* кире алу (бирелгән чекны); 3. *дипл. офиц.* ревокация, чакырып алу, кире кайтару (икенче илгә җибәрелгән илчене, вәкилне).

**РЕВОЛЬВЕ'Р** *м.* — револьвер, алтатар.

**РЕВОЛЬВЕ'РНЫЙ** — револьвер...-ы; *револьверный выстрел* — револьвер атуы, револьвердан ату. ◇ **Револьверный станок** *тех.* — револьверный станок (әйләнмәле башлы, камилләштерелгән кыру станогы).

**РЕВОЛЬВЕ'РЩИК** *м. спец.* — револьверщик, револьверный станокта эшләүче токарь.

**РЕВОЛЮЦИОНЕ'Р** *м.*, **РЕВОЛЮЦИОНЕ'РКА** *ж.* — революционер (1. революцион хәрәкәттә актив катнашучы көрәшче; 2. *перен.* революция ясаучы; революция ясаган кеше — берәр фән өлкәсендә тамырыннан үзгәреш кертсән, яңа юллар ачкан кеше; *революционер в науке* — фәндә революция ясаган кеше).

**РЕВОЛЮЦИОНИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.* — 1. революционлаштыру, революцион идеяләрне тарату; революцион рух бирү, революцион рухта тәрбияләү; *революционизировать массы* — массаны революционлаштыру; 2. *перен.* тамырыннан үзгәртү; *революционизировать технику* — техниканы тамырыннан үзгәртү.

**РЕВОЛЮЦИОНИЗИ'РОВАТЬСЯ** — 1. *сов.* и *несов. полит.* революционлашу, революцион рух алу, революцион рухта тәрбияләнү; 2. *несов. страд.* революционлаштырылу, революцион идеяләр белән сугарылу; төбе-тамырыннан үзгәртелү.

**РЕВОЛЮЦИОНИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.* — к. революционность.

**РЕВОЛЮЦИО'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет — революционлык, революцион рух, революцион идеяләр белән сугарылганлык.

**РЕВОЛЮЦИО'ННЫЙ** — революцион, революция...-ы; революцион рухлы, революциячел; революционлык белән сугарылган; *революционное движение* — революцион хәрәкәт; *революционный праздник* — революция бәйрәме.

**РЕВОЛЮ'ЦИЯ** *ж.* — 1. революция; *Великая Октябрьская социалистическая революция* — Бөек Октябрь социалистик революциясе; 2. *перен.* революция, үзгәреш, төбе-тамырыннан үзгәреш; кискен үзгәреш, революцион алмашыну; *культурная революция* — культура революциясе; *революция в производстве* — производствода революцион алмашыну.

**РЕВУ'Н** *м.* — 1. *разг.* елак, шыңшык, елак бала; 2. *зоол.* ревун, үкерүче маймыл (Көньяк Америкадагы маймылларның бер төре); 3. *мор.* сирена (пароходта).

**РЕВУ'НЬЯ** *ж. разг.* — елак кыз бала.

**РЕВЮ'** *ср. нескл.* — 1. *театр.* театр тамашасы (бер эчтәлеккә аерым күренешләрдән һәм номерлардан төзелгән постановка). 2. журнал. ревю (чит ил журналларына карата әйтелә).

**РЕГА'ЛИЯ** *ж.* — 1. *истор. торж.* регалия, падишаһлык билгесе (таҗ, скипетр һ. б. ш.); 2. *право, истор.* дәүләт монополиясе (акча сугу һ. б. ш. хокуклар); 3. *разг. шутл.* орден-медальләр; *явился во всех регалиях* — барлык орден-медальләрен тагып килгән иде; 4. *спец.* кыйммәтле сигара.

**РЕГА'ТА** *ж. спорт.* — регата (көймәдә узышу, көймәдә йөрү ярышларының бер төре).

**РЕ'ГБИ** *ср. нескл. спорт.* — регби (футбол уенының тупны кул белән тотарга мөмкин булган бер төре).

**РЕ'ГЕЛЬ** *м. плотн.* — регель, буй өрлек.

**РЕГЕНЕРА'Т** *м. тех.* — регенерат (файдаланылганнан соң яңадан азмы-күпме эшкә яраклы хәлгә кайтарылган материал).

**РЕГЕНЕРАТИ'ВНЫЙ** *тех. науч.* — 1. регенерация(ләү)...-ы; регенератив; яңадан эшкә яраклы хәлгә кайтару...-ы; *регенеративная печь* — регенерацияләү миче; 2. регенераторлы; *регенеративный приёмник* — регенераторлы радиоалгыч.

**РЕГЕНЕРА'ТНЫЙ** *тех.* — регенерацияләү...-ы; *регенератный завод* — регенерацияләү заводы (файдаланылган материалны яңадан эшкә яраклы хәлгә китерү заводы).

**РЕГЕНЕРА'ТОР** *м. тех.* — регенератор

**РЕМЕ'ДИУМ** *м. фин.*— ремедиум (алтын-көмеш акчаларның шомару сәбәпле үлчәүләре кимүнең закон тарафыннан рәсми рөхсәт ителгән чиге).

**РЕ'МЕЗ** *м. зоол.*— ремез (песнәкнең бер төре).

**РЕМЁННЫЙ** — каеш(тан ясалганлы); каешлы; *ремённый кнут* — каеш камчы; *ремённая передача (тех.)* — каешлы күчергеч.

**РЕМЕ'НЬ** *м.*— 1. каеш, бил каешы; *подпоясаться ремнём* — билгә каеш буу; 2. күн тасма, каеш бау; *ремень для правки бритв* — янау каешы (пәч пәкесе үткенли торган каеш кисәге); 3. *тех.* тапшыру каешы (хәрәкәтне бер шкивтан икенче шкивка тапшыра торган, очсыз тоташ каеш яки махсус тукымадан эшләнгән киң тасма); 4. *только мн.* багаж каешы, багаж ремене. ◇ **Чересседельный ремень** — аркалык. **Подбрюшный ремень** — бавыргалык, түшлек.

**РЕМЕ'СЛЕННИК** I *м.*— 1. һөнәрче, һөнәрле кеше; оста; *пригород ремесленников* — һөнәрчеләр бистәсе; 2. *перен. пренебр.* кустарь, кәсепче (ягъни иҗади рухланусыз шаблон буенча өстән-өстән генә эшләүче, миннән киткәнче, нясенә җиткәнче дип эшләүче).

**РЕМЕ'СЛЕННИК** II *м.*— һөнәр мәктәбе укучысы.

**РЕМЕ'СЛЕННИЦА** *ж.*— к. ремесленник I, II.

**РЕМЕ'СЛЕННИЧАТЬ** *несов. разг.*— 1. һөнәрче булу, һөнәрчелек итү, кул һөнәрләре белән шөгыльләнү (балта осталыгы, сәгать төзәтү һ. б.); 2. *перен. пренебр.* кустар(лар)ча эшләү, шаблон белән эшләү, бер калыптан сугу, иҗади башлангычсыз эшләү.

**РЕМЕ'СЛЕННИЧЕСКИЙ** *пренебр.*— кустарьларча...; *ремесленническое отношение к искусству* — сәнгатькә кустарьларча мөнәсәбәт.

**РЕМЕ'СЛЕННИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет — к. ремесленничать.

**РЕМЕ'СЛЕННЫЙ** — 1. һөнәр ...-ы; *ремесленное училище* — һөнәр мәктәбе; 2. һөнәрче(лек)...-ы; *ремесленный труд* — һөнәрчелек хезмәте; 3. *перен.* тупас, кустарь; кустарь(лар)ча; *ремесленная работа* — кустарь эш, тупас эш; *ремесленное отношение к живописи* — сынлы сәнгатькә кустарь(лар)ча мөнәсәбәт; 4. *истор.* һөнәрчеләр...-ы; *ремесленная управа* — һөнәрчеләр идарәсе.

**РЕМЕСЛО'** *ср.*— 1. һөнәр, осталык, кул эше; *переплётное ремесло* — китап төпләү һөнәре; *плотничье ремесло* — балта осталыгы; 2. *перен.* эш, хезмәт, кәсеп; *приняться за старое ремесло* — элекке эшенә керешү, элекке кәсебенә кайту.

**РЕМЕ'ШЕЧНИК, РЕМЕ'ШНИК** *м. спец.*— ременьчы, каешчы, каеш эшләүче (эшче, белгеч).

**РЕМЕШКО'ВЫЙ** — каеш..., каештан үрелгән, каеш тасмадан ясалган (ишелгән); *ремешковый кнут* — каеш камчы, каештан үрелгән камчы.

**РЕМЕШО'К** *м.*— (кечкенә) каеш; *ремешок для часов* — сәгать каешы.

**РЕМИ'З** *м. спец.*— ремиз (1. кайсы бер карта уеннарында тиешле взятка җыя алмый калу һәм шуның өчен штраф; 2. *тех.* к. ремиза 1; 3. *спорт.* фехтованиедә — кисәтү удары, чәнчү; 4. *охот. устар.* киек ята торган урын; яткылык; *заячий ремиз* — куян яткылыгы; 4. *фин.* күчерелмә вексель буенча акча түләү).

**РЕМИ'ЗА** *ж. спец.*— ремиза (1. *тех.* туку станогында: очлары элмәкле җепләр белән тоташтырылган ике агач планка; 2. *тех. редко* туку станында буй җепләрне үткәрә торган тишек, көре; 3. *мн. торг.* кыйпылчыклар, кисәк-косак, калдык-постык ситсы кисәкләре).

**РЕМИ'ЗИТЬ** *несов.*— 1. (карта уенында) ремиз ясап оттырту; 2. *перен. разг. фам.* к. обремизить.

**РЕМИ'ЗИТЬСЯ** *несов.*— 1. карта уенында: тиешле санда взятка җыя алмыйча отылу; 2. *перен. разг. фам.* к. обремизиться;

**РЕМИ'ЗКА** *ж. тех.*— к. ремиза 1.

**РЕМИ'ЗНИК** *м.*, **РЕМИ'ЗНИЦА** *ж. спец.*— ремизник (туку станогының бер өлеше белән идарә итүче эшче).

**РЕМИ'ЗНЫЙ** *тех. текст.*— ремиза...-ы; *ремизный аппарат* — ремиза аппараты (туку промышленностендә).

**РЕМИЛИТАРИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *полит.*— ремилитаризация, кабат хәрбиләштерү, янадан хәрбиләштерү (халыкара договор буенча коралсызландырылган дәүләтнең кораллы көчләрен һәм хәрби промышленностен торгызу).

**РЕМИЛИТАРИЗИ'РОВАТЬ** *сов. и несов. полит.*— ремилитаризацияләү, ремилитаризация үткәрү, кайтадан хәрбиләштерү, янадан кораллантыру, кораллы көчләрне торгызу.

**РЕМИЛИТАРИЗИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. полит.*— ремилитаризация үткәрелү, янадан кораллантырылу, кораллы көчләр торгызылу.

**РЕМИЛИТАРИЗОВА'ТЬ** *сов. и несов. полит.*— к. ремилитаризировать.

**РЕМИЛИТАРИЗОВА'ТЬСЯ** *несов. страд. полит.*— к. ремилитаризироваться.

**РЕМИНГТО'Н** *м.*— ремингтон (аерым төр язу машинкасы).

**РЕМИНГТОНИ'СТ** *м.*, **РЕМИНГТОНИ'СТКА** *ж. канц. устар.*— машинистка (ремингтон маркалы язу машинкасында эшләүче).

**РЕМИНИСЦЕ'НЦИЯ** *ж. книж.*— реминисценция (1. тонык хатирәләр, истәлекләр; искә төшерә, хәтерләтә торган нәрсәләр; 2. *лит.* матур әдәбият әсәрендә тема һәм стиль ягыннан охшаш булган икенче бер әсәрнең яңгырашы булу, ихтыярсыз йогынтысы сизелү).

**РЕМИ'ССИЯ** *ж.*— ремиссия (1. *мед.* авыруның кимүе, узуы, авыру күренешләренең югала, бетә баруы; 2. *фин.* кире кайтару — банк һәм биржа эшләрендә исәп-хисапны өзгәндә кыйммәтле әйберләрне кайтарып бирү; 3. *торг.* түләүне түгәрәкләү өчен, счёттагы суммадан ясалган киметмә, ташлама).

**РЕМИТЕ'НТ** *м. фин.*— ремитент (күчерелмә вексель белән акча алучы).

**РЕМИТИ'РОВАТЬ** *сов. и несов. фин.*— күчерелмә вексель белән акча җибәрү акча күчерү.

**РЕМИТИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. фин.*— күчерелмә вексель белән акча җибәрелү.

**РЕМНЕ'Ц** *м. зоол.*— тасма суалчан (су кошлары һәм балык тәнендәге паразит суалчан).

**РЕМНЕЦВЕ'ТНИК** *м. бот.*— тасмачәчәк, тасмачәчәк куагы (тропик якларда һәм СССР ның көньягында үсә торган куак үсемлек).

**РЕМНЕЦВЕ'ТНЫЕ** *мн. бот.*— тасмачәчәкләләр, тасмачәчәкләләр семьялыгы.

**РЕМО'НТ** *м.*— 1. ремонт, ремонтлау, ремонт ясау, төзәтү; *ремонт одежды* — кием-салымны ремонтлау (ямау); *ремонт дома* — өйгә ремонт ясау; 2. *воен. устар.*

ремонт (гаскәр өчен ат алу, гаскәрдә кимегән ат санын тутыру); 3. *с.-х.* тутыру, яңарту, тиешле санга җиткерү; *ремонт стада* — көтүне тутыру (яшь терлекләр хисабына).◇ **Капитальный ремонт** — капиталь ремонт (берәр бинаны яки оборудованиене тулысынча элекке хәленә кайтару ремонты). **Текущий ремонт** — агымдагы ремонт. **Профилактический ремонт** *тех.*— профилактик ремонт (машиналарның бөтенләй эштән чыгып, зур ремонтка мохтаҗ булуларына юл куймау өчен, вакыты-вакыты белән үткәрелә торган ремонт).

**РЕМОНТЁР** *м. воен. устар.*— ремонтёр (элекке Россиядә гаскәр өчен кирәкле атлар җыючы).

**РЕМОНТИ'РОВАНИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— к. ремонтировать.

**РЕМОНТИ'РОВАТЬ** *сов. и несов.*— 1. ремонтлау, ремонт ясау, ремонт үткәрү (төзәтү, ямау, сипләү); 2. *воен.* атлар санын тутыру, кирәкле санга җиткерү.

**РЕМОНТИ'РОВАТЬСЯ** — 1. *несов. страд.* ремонтлану, ремонт үткәрелү, ремонт ясалу (төзәтелү, сипләтелү, ямалу); 2. *сов. и несов. перен. фам. шутл.* сәламәтлекне ныгыту, бераз дәвалану, дәваланып алу; *поеду нынче в Крым ремонтироваться* — быел сәламәтлегемне ныгыту өчен Кырымга барам.

**РЕМОНТИРО'ВКА** *ж. мн.* нет, *просторeч.*— к. ремонтировать 1; *ремонтировка здания* — бинаны ремонтлау.

**РЕМО'НТНИК** *м. спец.*— ремонт(лау)чы, ремонт ясаучы, ремонт эшчесе.

**РЕМО'НТНЫЙ** — 1. ремонт(лау)...-ы; ремонт ясау...-ы; ремонт ясый торган, ремонтлый торган; *ремонтные работы* — ремонт(лау) эшләре; *ремонтные мастерские* — ремонт ясау мастерскойлары; 2. ремонт ясаучы, ремонт үткәрүче, ремонт(лау)чы; *ремонтные рабочие* — ремонт ясаучы эшчеләр, ремонтлаучылар; 3. *воен.* ремонт...-ы; тутыру өчен алынган; *ремонтные лошади* — ремонт атлары (гаскәрдә кимегән ат санын тутыру өчен алынган атлар); 4. *с.-х.* үрчем...-ы; үрчем алу өчен асрала торган; *ремонтная матка* — үрчем анасы.

**РЕМОНТУА'Р** *м. устар.*— боргыч (кесә сәгатен ачкычсыз бору өчен махсус җайланма).

**РЕНАТУРАЛИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *офиц.*— ренатурализация, гражданлык хокукын торгызу (берәр сәбәп белән билгеле бер илдә гражданлык хокукын югалткан кешегә ул хокукны яңадан кайтару).

**РЕНАТУРАЛИЗОВА'ТЬ** *сов. и несов. офиц.*— гражданлык хокукын торгызу, кире кайтару.

**РЕНАТУРАЛИЗОВА'ТЬСЯ** *офиц.*— 1. *сов. и несов.*— ренатурализацияләнү, гражданлык хокукын кайтарып алу; 2. *несов. страд.* ренатурализация ясалу, гражданлык хокукы торгызылу.

**РЕНГЛО'Т** *м. мн.* нет, *просторeч.*— к. ренклод.

**РЕНЕГА'Т** *м.*, **РЕНЕГА'ТКА** *ж. книж. презрит.*— ренегат, мөртәт (үзенең элекке карашларына хыянәт иткән һәм дошман ягына кучкан кеше).

**РЕНЕГА'ТСКИЙ** *книж. презрит.*— ренегат...-ы; ренегатка хас, ренегатларча...; *ренегатский поступок* — ренегатларча эш итү.

**РЕНЕГА'ТСТВО** *ср. мн.* нет, *книж. презрит.*— ренегатлык, мөртәтлек, сатылу, хаинлык.

**РЕНЕГА'ТСТВОВАТЬ** *несов. книж. презрит.*— ренегат булу, мәсләгенә хыянәт итү, фикереннән кайту (дүнү).

**РЕНЕССА'НС** *м. мн.* нет, *книж.*— 1. *истор. лит. искус.* Ренессанс, Яңарыш, Яңарыш чоры (15—16 гасырларда Көнбатышта фән һәм сәнгатьнең күтәрелеш һәм чәчәк атыш чоры); 2. *арх.* Яңарыш чорындагы архитектура стиле; 3. уяну, яңару, күтәрелеш.

**РЕНЕ'Т** *м. мн.* нет — к. ранет.

**РЕНКЛО'Д** *м. мн.* нет — ренклод (бик эре, тәмле һәм суслы караҗимеш төре).

**РЕНОМЕ'** *ср. нескл. книж.*— берәр кеше турында урнашкан фикер, репутация, абруй; *у него хорошее реноме* — аның турында һәркем яхшы фикердә, аның репутациясе яхшы.

**РЕНО'НС** *м. спец.*— ренонс, мач юклык (карта уенында нинди дә булса бер мачның уйнаучыда булмавы); *ренонс в пиках* — пикилар юк, пикилар килмәде; *ходить в ренонс* — каршы уйнаучыда булмаган мач белән чыгу.

**РЕ'НСКОВЫЙ: ренсковый погреб** *устар.*— шәрап подвалы, шәрап кибете (кызыл аракы сата торган кибет).

**РЕ'НТА** *ж. экон.*— рента (капиталистик илләрдә капиталдан, җирдән яки кыйммәтле кәгазьләрдән бернинди дә хезмәт куймыйча даими алына торган процент, килер).

**РЕНТА'БЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *экон.*— рентабельлек, табышлылык, файдалылык (үзенә тотылган чыгымны каплый алырлык булу).

**РЕНТА'БЕЛЬНЫЙ** *экон.*— (хуҗалык ягыннан) рентабельле, файдалы, табышлы; үз чыгымнарын каплый торган, расходын күтәрә торган; *рентабельное предприятие* — рентабельле предприятие, табышлы предприятие.

**РЕНТГЕ'Н** *м. мед. разг.*— 1. рентген, рентген нурлары; 2. рентген аппараты; 3. *только ед.* рентгенда карау (рентген нурлары ярдәме белән эчке әгъзаларның авыру яки авыру түгеллеген билгеләү).

**РЕНТГЕНИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *мед.*— к. рентгенизировать.

**РЕНТГЕНИЗИ'РОВАТЬ** *сов. и несов. мед.*— 1. рентген белән карау; 2. рентген нурлары белән дәвалау, рентген нурында тоту.

**РЕНТГЕНИЗИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. мед.*— рентген нурлары белән дәвалану; рентген нуры астында тотылу.

**РЕНТГЕ'НОВСКИЙ** *физ.* — рентген...-ы;

*рентгеновский кабинет* — рентген кабинеты; *рентгеновские лучи* — рентген нурлары.

**РЕНТГЕНОГРА'ММА** *ж. мед. физ.*— рентгенограмма (рентген нурлары ярдәмендә төшерелгән фоторәсем).

**РЕНТГЕНОГРАФИ'ЧЕСКИЙ** *мед. физ.*— рентгенография...-ы; рентгенографик, рентгенография юлы белән...; *рентгенографический анализ* — рентгенографик анализ.

**РЕНТГЕНОГРА'ФИЯ** *ж. мн.* нет — рентгенография (1. *мед.* рентген нурлары ярдәмендә рәсем төшерү; 2.*физ.* матдәләрне рентген нурлары ярдәме белән тикшерү алымнары турындагы белем).

**РЕНТГЕНО'ЛОГ** *м. мед.*— рентгенолог, рентгенология белгече (рентгенология һәм рентгенотерапия белгече, врач).

**РЕНТГЕНОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** *мед.*— рентгенологик, рентгенология...-ы; *рентгенологический кабинет* — рентгенология кабинеты.

**РЕНТГЕНОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет — рентгенология (1. рентген нурлары һәм аларны куллану турындагы белем; 2. *мед.* медицинаның рентген нурлары белән дәвалау турындагы бүлеге).

**РЕНТГЕНОСКОПИ'ЧЕСКИЙ** *мед. тех.*— рентгеноскопик; рентгеноскопияләү...-ы; *рентгеноскопическая практика* — рентгеноскопияләү (рентген белән карау) практикасы.

**РЕНТГЕНОСКОПИ'Я** *ж. мн.* нет, *мед. тех.*— рентгеноскопия (рентген нурлары ярдәмендә карау һәм тикшерү).

**РЕНТГЕНОТЕРАПИ'Я** *ж. мн.* нет, *мед.*— рентгенотерапия, рентген нурлары белән дәвалау.

**РЕ'НТНЫЙ** *фин. экон.*— 1. рента...-ы; рентадан килгән; *рентный доход* — рентадан доход; *рентный банк* — рента банкы; 2. ренталы; *рентный заём* — ренталы заём.

**РЕОМЮ'Р** *м. мн.* нет, *физ.*— реомюр, реомюр термометры (боз эрү ноктасы белән су кайнау ноктасы 80 градуска гына бүленгән термометр).

**РЕОРГАНИЗАЦИО'ННЫЙ** — реорганизация...-ы; үзгәртеп кору...-ы, янача төзү...-ы; янача оештыру...-ы; *реорганизационный период* — реорганизация чоры, үзгәртеп кору чоры.

**РЕОРГАНИЗА'ЦИЯ** *ж.*— реорганизация(ләү), янача төзү, янача оештыру, үзгәртеп кору; *реорганизация управления* — идарә итүне үзгәртеп кору; *реорганизация производства* — производствоны янача кору, үзгәртеп кору.

**РЕОРГАНИЗОВА'ТЬ** *сов. и несов.*— реорганизацияләү, үзгәртеп кору, янача төзү, янача оештыру, реорганизация (үзгәреш) кертү.

**РЕОРГАНИЗОВА'ТЬСЯ** *сов. и несов.*— реорганизацияләнү, үзгәртелү, үзгәртеп төзелү, янача корылу, үзгәреш кертелү.

**РЕОРГАНИЗО'ВЫВАТЬ** *несов.*— к. реорганизовать.

**РЕОРГАНИЗО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.*— к. реорганизоваться.

**РЕОСТА'Т** *м. физ.*— реостат (электр агымының көчен һәм көчәнешен үзгәртү, тигезләү приборы).

**РЕОХО'РД** *м. физ.*— реохорд (җисемнәрнең электр каршылыгын төгәл үлчәү өчен кулланыла торган аппарат).

**РЕ'ПА** *ж.*— шалкан.◇ **Дешевле пареной репы** — шалкан бәясе (бик арзан).

**РЕПАРАЦИО'ННЫЙ** *полит.*— репарация...-ы; репарацион, репарация буенча тиешле; *репарационные платежи* — репарация түләүләре, репарация буенча тиешле түләүләр.

**РЕПАРА'ЦИЯ** *ж. полит.*— репарация (сугыш аркасында килгән зарарларны тулысынча яки өлешчә каплау өчен, җиңелгән дәүләттән җиңгән дәүләткә акчалата яисә әйберләтә түләүләр).

**РЕПАТРИА'НТ** *м.*, **РЕПАТРИА'НТКА** *ж. полит.* — репатриант (репатриация тәртибендә иленә кайтучы кеше).

**РЕПАТРИА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *полит.*— репатриация, репатриацияләү (сугыш әсирләренең, качакларның, дошман тарафыннан чит илгә куылган кешеләрнең кире үз ватаннарына кайтарылуы).

**РЕПАТРИИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. полит.*— репатрияцияләү, үз иленә (ватанына) кайтару.

**РЕПАТРИИ'РОВАТЬСЯ** *полит.*— 1. *сов.* и *несов.* үз иленә кайту, репатриацияләнү; 2. *несов. страд.* ватанына кайтарылу, репатриация ясалу (үткәрелү).

**РЕПЕЁК** *м. спец.*— шпор тәгәрмәче (шпорның үткен сырлы йолдызсыман кечкенә тәгәрмәче).

**РЕПЕ'Й** *м. разг.*, **РЕПЕ'ЙНИК** *м.*— 1. *(лопух)* әрекмән; 2. кырмавык, тигәнәк (картайган әрекмәннең чәчечкеле чәчәге, башы); *лошадь с репейниками в спутанной гриве* — ялына кырмавык сарып беткән ат.

**РЕПЕ'ЙНЫЙ** — әрекмән...-ы, тигәнәк...-ы, кырмавык...-ы; *репейное семя* — әрекмән орлыгы.◇ **Репейное масло** — чәч мае (әрекмән тамырын агач маенда тотып ясалса да, халыкта ягыш „шалкан мае“ дип йөртәләр).

**РЕПЕ'ЙНИЦА** *ж. зоол.*— әрекмән күбәләге.

**РЕПЕ'Р** *м.*— репер (җир өсте тигезлеген үлчәгәндә, чагыштырма билге итеп куела торган казык, багана, һ. б. ш.).

**РЕПЕРТУА'Р** *м. мн.* нет — репертуар (1. берәр театрда сәхнәдә уйнала торган яки куярга билгеләнгән пьесалар; *новый репертуар* — яңа репертуар, яңа пьесалар; *классический репертуар* — классик әдәбият әсәрләреннән торган репертуар; 2. бер артистның барлык башкара торган рольләре; 3. *перен. книж.* запас, белем; *у него большой репертуар поговорок и метких выражений* — ул бик күп әйтемнәр, тапкыр сүзләр белә).

**РЕПЕРТУА'РНЫЙ** — репертуар...-ы; *репертуарный комитет* — репертуар комитеты.

**РЕПЕТИ'Р** *м. устар. спец.*— репетир, суккыч (элекке куен сәгатьләренең сугу механизмы).

**РЕПЕТИ'РОВАТЬ** *несов.*— 1. репетиция ясау, өйрәнү, куярга хәзерләү; *репетировать пьесу* — пьесаны куярга хәзерләү, репетиция ясау; 2. *(помогать кому-н. в прохождении курса)* хосусый укыту, өйдә дәресләр бирү; өлгерми торган укучыга сабагын өйрәтү, ярдәм итү, булышу, имтиханга хәзерләү.

**РЕПЕТИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.*— репетиция ясалу, куярга хәзерләнелү.

**РЕПЕТИ'ТОР** *м.*— репетитор, хосусый укытучы (дәресеннән өлгермәгән укучыга өенә килеп сабак өйрәтүче).◇ **Часы с репетитором** — суккычлы сәгать.

**РЕПЕТИ'ТОРСКИЙ** — репетитор(лык) ...-ы; *репетиторская работа* — репетитор (лык) эше.

**РЕПЕТИ'ТОРСТВО** *ср. мн.* нет — репетиторлык, репетиторлык эше.

**РЕПЕТИ'ТОРСТВОВАТЬ** *несов.*—репетитор булып эшләү, репетиторлык итү, өйдә сабак укыту (өйрәтү) белән шөгыльләнү.

**РЕПЕТИЦИО'ННЫЙ**—репетиция...-ы; *репетиционный зал* — репетиция залы.

**РЕПЕТИ'ЦИЯ** *ж.*— 1. репетиция (сәхнәгә кую алдыннан пьесаны хәзерләү, өйрәнү, уйнап карау); *последняя репетиция* — соңгы репетиция; 2. ясап (тикшереп, сынап) карау; *репетиция парада* — парад ясап карау; 3. *перен.* репетиция, хәзерлек; *революцию 1905 года Ленин назвал репетицией Октября* — 1905 ел революциясен Ленин Октябрьның репетициясе дип атады; 4. *устар.* сәгать сугуы, сугу механизмы; *часы с репетицией* — суга торган кесә сәгате.

**РЕПЕТОВА'ТЬ** *сов. и несов мор.*: репетовать сигналы — сигналларны кабатлау (дөрес аңлаганны күрсәтү өчен, кабул итүченең шул ук сигналларны яңадан кабатлавы).

**РЕ'ПИНА** *ж. простореч.*— бер шалкан, бер баш шалкан.

**РЕ'ПИЦА** *ж.* — койрык төбе, койрык (хайваннарның).

**РЕ'ПЛИКА** *ж.*— 1. реплика, урыннан искәрмә, урыннан каршы әйтү, сүз кыстыру, сүз кушу (берәү сөйләгәндә аңа каршы төшеп яки җавап итеп кыскача әйтелгән сүз); 2. *театр.* реплика (бер артистның икенче артист сөйләве алдыннан булган соңгы сүзләре); 3. *право* реплика, каршы килү, дәгъва (суд барышында берәр якның ризасызлык күрсәтүе); 4. *муз.* музыканың бер өлешен башка тавыш белән кабатлау (тәкрарлау).

**РЕПЛИЦИ'РОВАТЬ** *сов. и несов.*— 1. реплика ясау, реплика кыстыру; 2. *театр.* реплика әйтү (к. реплика 2); 3. *муз.* к. реплика 4.

**РЕ'ПНЫЙ** — шалкан...-ы; *репный вкус* — шалкан тәме.

**РЕПНЯ'К** *м. мн.* нет — шалкан яфраклары, сабаклары.

**РЕПО'ВНИК** *м. бот.*— эт какысы, тиле шалкан.

**РЕ'ПОВЫЙ** — шалкан...-ы; *реповый отвар* — шалкан суы (шалкан пешергән су).

**РЕПОЗИ'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *мед.*— репозиция, утырту (чыккан, тайган, биртелгән сөяк-буыннарны).

**РЕПОЛО'В** *м. зоол.*— киндер чыпчыгы, кура чыпчыгы (кечкенә сайрар кош).

**РЕПО'РТ** *м.*— репорт (1. *фин.* биржада спекулятив операция — кыйммәтле кәгазьләрнең сатылу вакытын кичектерү турында килешү; 2. *бух.* сумманы бер биттән икенче биткә күчереп язу).

**РЕПОРТА'Ж** *м. мн.* нет — 1. репортаж (берәр эшнең яисә ярышның барышын телдән әйтеп, белдереп тору); *репортаж по радио о футбольном состязании* — футбол ярышы турында радио аша репортаж; 2. репортёрлык эше, газета өчен хәбәрләр җыю эше.

**РЕПОРТЁР** *м.*— репортёр, хәбәрче (газетага урындагы вакыйгалар турында хәбәрләр бирер торучы).

**РЕПОРТЁРСКИЙ** — репортёр...-ы; *репортёрская заметка* — репортёр мәкаләсе.

**РЕПОРТЁРСТВО** *ср. мн.* нет — репортёрлык, репортёр эшчәнлеге.

**РЕПОРТЁРСТВОВАТЬ** *несов.*— репортёр (урындагы хәбәрче) булу, репортёрлык итү, репортёр булып эшләү.

**РЕПРЕЗЕНТА'НТ** *м. книжн.*— вәкил.

**РЕПРЕЗЕНТА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *книжн.*— вәкиллек, вәкил булу(чылык).

**РЕПРЕЗЕНТИ'РОВАТЬ, РЕПРЕЗЕНТОВА'ТЬ** *сов. и несов. книжн.*— вәкиллек итү, вәкил булу, вәкил булып тору.

**РЕПРЕЗЕНТИ'РОВАТЬСЯ, РЕПРЕЗЕНТОВА'ТЬСЯ** *несов. страд. книжн.*— вәкил итеп куелу, вәкил итеп җибәрелү (тәкъдим ителү).

**РЕПРЕССА'ЛИИ** *мн. полит.*— 1. репрессалилар (халыкара мөнәсәбәтләрдә — бер дәүләтнең икенче бер дәүләт органнарына һәм гражданнарына карата көчләү чаралары кулланууына каршы җавап итеп, аның да гражданнарына һәм оешмаларына карата шундый ук кысулар куллану); 2. *устар.* репрессияләр, кысулар, җәзалау (бастыру) чаралары; *на студенческие волнения царское правительство отвечало репрессалиями* — студентлар чуалышына патша хөкүмәте репрессияләр белән җавап бирә иде.

**РЕПРЕССИ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книжн.*— репрессивлык, репрессияләр куллану; бастыру (җәза) чаралары куллану.

**РЕПРЕССИ'ВНЫЙ** *книжн.* — репрессив, репрессия...-ы; җәзалау (кысу, бастыру)...-ы; *репрессивные меры* — җәзалау чаралары, бастыру чаралары.

**РЕПРЕССИ'РОВАТЬ** *сов. и несов. книжн.*— репрессия (көч) куллану, репрессияләү, кысу, бастыру (җәза) чаралары куллану.

**РЕПРЕССИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. книжн.*— репрессиягә (җәзага) тартылу, җәзалану, бастырылу.

**РЕПРЕ'ССИЯ** *ж. книж.*— репрессия, җәзалау чарасы, бастыру (кысу) чаралары.

**РЕПРИ'З** *м.*, **РЕПРИ'ЗА** *ж.*— реприз (1. *воен. спорт.* атның элекке аллюрга күчүе, элекке йөрешенә кайтуы; *реприз рыси, после прохождения препятствия*— киртәне узгач, атның яңадан юртуга күчүе; 2. *муз.* кабатлану, кабатлау билгесе (көйнең мәгълүм бер өлеше кабатлану һәм нотада шуның билгесе); 3. *театр.* сәхнәгә яңадан кайту, яңадан менү, кайтадан куела башлау (пьеса турында).

**РЕПРИМА'НД** *м. разг. устар.*— шелтә, каты кисәтү.

**РЕПРОДУКТИ'ВНЫЙ** *псих.*: репродуктивный процесс — репродукция процессы, искә төшерү (хәтерләү) процессы.

**РЕПРОДУ'КТОР** *м. радио* — репродуктор, тавыш көчәйткеч.

**РЕПРОДУКЦИО'ННЫЙ** *тип.*— репродукция(ләү)...-ы; *репродукционный аппарат* — репродукцияләү аппараты; *репродукционные мастерские* — репродукцияләү мастерскойлары.

**РЕПРОДУ'КЦИЯ** *ж.*— репродукция (1. *тип.* фото, клише һ. б. белән рәсемнәрне репродукцияләү, репродукция ясау; рәсемнең күчермәсен алып күбәйтү; 2. *искус.* репродукция, күчермә картина, репродукция юлы белән ясалган рәсем; *репродукции картин Репина* — Репин рәсемнәренең репродукцияләре; 3. *псих.* күңелдә калганны яңарту, хәтергә төшерү, искә төшерү, күз алдына китерү).

**РЕПРОДУЦИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.*— 1. *тип.* репродукция ясау, рәсемнәрнең күчермәсен алу; 2. *псих.* истә калганны яңарту, хәтердә яңарту, искә төшерү; *репродуцировать в памяти* — хәтердә яңарту.

**РЕПРОДУЦИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. книж.*— репродукция ясалу, яңартылу; күчермәсе алыну, күчермәсе алынып күбәйтелү (таратылу).

**РЕПС** *м. мн.* нет — репс (калын тукыма төре).

**РЕ'ПСОВЫЙ** — репс...; репстан эшләнгән; *репсовая обивка* — репс тышлык (репстан эшләнгән тышлык).

**РЕПТИ'ЛИЯ** *ж.*— 1. *зоол.* рептилия, сөйрәлүче хайван (елан, ташбака, кәлтә һ. б. ш.); 2. *перен. презрит.* сатлык җан, вак (түбән) җан; 3. *перен. презрит.* сатлык буржуаз матбугат, сатлык журналист, сатлык газетчы.

**РЕПТИ'ЛЬНЫЙ** *презрит.*— сатылган, сатлык; *рептильная пресса* — сатлык матбугат.

**РЕПУТА'ЦИЯ** *ж.*— репутация, абруй, дан, шөһрәт (бер кешенең яхшы яки яман яги турында таралган фикер); *приобрести дурную репутацию* — исеме чыгу, яман аты чыгу, телгә керү; *пользоваться хорошей репутацией* — кеше арасында игътибарлы булу, яхшы репутацияле булу; *испортить репутацию кому-н.*— намусын пычрату, яхшы исеменә тап төшерү, репутациясен бозу.

**РЕ'ПЧАТЫЙ**: репчатый лук — башлы суган.

**РЕСКО'НТРО** *нескл. ср. бухг.*— рескон- тро (хосусый исәп-хисапларны яза торган бухгалтерия кенәгәсе).

**РЕСКРИ'ПТ** *м. устар.*— рескрипт (1. патшаның берәр югары дәрәҗәле кешегә мактау, рәхмәт һ. б. ш. белдереп язган хаты; 2. *истор.* борынгы Римда императорның закон көченә ия булган җавап белдермәсе).

**РЕ'СМУС** *м.*— к. рейсмас.

**РЕСНИ'ЧАТЫЙ, РЕСНИ'ТЧАТЫЙ** *зоол.*— к. ресничный 2.

**РЕСНИ'ЦА** *ж.*— керфек.

**РЕСНИ'ЧКА** *ж.*— 1. керфеккәй, керфекчек; 2. *биол.* төк, җепсел (хайван күзәнәкләрендә булган җепсыман нечкә үсенте).

**РЕСНИ'ЧНЫЙ** — 1. керфек...-ы; 2. төкле, җепселле; керфекле; *ресничные черви* — төкле суалчаннар; *ресничные инфузории (биол.)*— керфекле инфузорияләр.

**РЕСПЕ'КТ** *м. устар.*— хөрмәт(ләү), олылау, ихтирам итү.

**РЕСПЕКТА'БЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж. устар.*, *теперь ирон. шутл.*— дәрәҗәле булу, олысымаклык, могтәбәрлелек.

**РЕСПЕКТА'БЕЛЬНЫЙ** *книж. устар.*, *теперь ирон. шутл.*— хөрмәтле, олысымак, дәрәҗәле, өлкән, мөхтәрәм, могтәбәр.

**РЕСПИРА'ТОР** *м.*— респиратор (сулаганда тузан һәм агулы газ кермәсен өчен борынга һәм авызга киелә торган җайланма, мәсәлән, агулы газлар бүленеп чыга торган шахталарда).

**РЕСПИРАТО'РНЫЙ** — респирацияле, сулыш...-ы; *респираторные звуки* — респирацияле авазлар, сулыш авазлары (сулыш алганда чыга торган авазлар). ◇ **Респираторные судороги** *мед.*— интегеп сулыш алу, тын кысылу.

**РЕСПИРА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *мед.*— респирация, сулау, сулыш алу, тын алу.

**РЕСПУ'БЛИКА** *ж. полит.*— республика (1. югары власть органнары мәгълүм срокка сайланып куела торган дәүләт төзелеше; 2. идарә итү формасы шундый булган ил, дәүләт).

**РЕСПУБЛИКА'НЕЦ** *м.*, **РЕСПУБЛИКА'НКА** *ж. полит.*— 1. республикачы, республика яклы кеше, республика тарафдары (монархиягә каршы кеше); 2. республиканец (АКШта реакцион республиканецлар партиясе члены).

**РЕСПУБЛИКА'НСКИЙ** *полит.*— 1. республика...-ы; *республиканский флаг* — республика флагы; 2. республикачы, республика юлы белән...; *республиканские партии* — республикачы партияләр; *республиканский образ правления* — республика юлы белән идарә итү; 3. республика күләмендәге, республика карамагындагы; *республиканский съезд учителей Татарии* — Татарстан укытучыларының республика күләмендәге съезды. ◇ **Республиканский календарь** —

Республика календаре (Франциядә 1793 елда революцион конвент тарафыннан кабул ителгән календарь).

**РЕССО'РА** *ж.*— рессор, сиртмә; *коляска на рессорах* — сиртмәле коляска; *рессоры автомобиля* — автомобиль рессорлары.

**РЕССО'РНЫЙ** — 1. рессор...-ы; *рессорный болт* — рессор болты; 2. рессорлар ясаучы; *рессорный мастер* — рессорлар ясаучы мастер; 3. рессорлы, сиртмәле, пружиналы; *рессорный экипаж* — рессорлы экипаж, сиртмәле экипаж; 4. рессорлык; *рессорная сталь* — рессорлык корыч (рессора ясау өчен).

**РЕССО'РЩИК** *м. спец.* — рессорчы, рессорлар ясаучы (эшче яки белгеч).

**РЕССУ'РС** *м.*— к. ресурс.

**РЕСТАВРА'ТОР** *м.*— 1. реставрацияләүче, реставрация ясаучы, реставратор (сәнгать-архитектура памятникларын яңадан элекке хәленә кайтаручы белгеч); *художник-реставратор* — реставрацияләүче художник; 2. *полит.* реставратор, реставрацияче, реставрация яклы, реставрация тарафдары (революция тарафыннан бәреп төшерелгән иске стройны кайтарырга омтылучы).

**РЕСТАВРА'ТОРСКИЙ** *полит.*— реставрация(ләү)...-ы; реставраторлык...-ы; искене торгызырга (кайтарырга) тырышу...-ы; *реставраторские попытки* — реставраторлык омтылышлары (иске стройны торгызырга маташулар).

**РЕСТАВРА'ТОРСТВО** *ср. мн.* нет, *искус.*— реставраторлык, реставрацияләү эше.

**РЕСТАВРАЦИ'ОННЫЙ** *искус.*— реставрацияләү (торгызу, яңарту)...-ы; *реставрационная мастерская* — реставрацияләү мастерское (иске әйберләрне элекке хәленә кайтару мастерское).

**РЕСТАВРА'ЦИЯ** *ж.*— реставрация, реставрацияләү, реставрация ясау (1. *искус.* борынгы памятникларны торгызу, элекке хәленә китерү, элекке хәленә кайтару; яңарту; *реставрация картины* — рәсемгә реставрация ясау; *реставрация дворца* — сарайны реставрацияләү, яңарту; 2. *искус.* реставрацияләнгән әйбер, яңадан торгызылган әйбер; 3. *полит.* революция бәреп төшергән властьны яңадан торгызу, яңадан кайтару).

**РЕСТАВРИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— 1. *искус.* реставрация ясау, реставрацияләү; торгызу; элекке хәленә кайтару, яңарту; *реставрировать памятники старины* — борынгы памятникларны реставрацияләү; 2. *полит.* кире кайтару, яңадан торгызу, реставрацияләү; *никому не удастся реставрировать капитализм в Советской стране* — беркем дә Советлар илендә капитализмны кире кайтара алмаячак.

**РЕСТАВРИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. реставрацияләнү, реставрация ясалу; торгызылу, элекке хәленә китерелү, яңартылу; 2. кире кайтарылу, яңадан торгызылу.

**РЕСТИТУ'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — реституция (1. *право* хокукны торгызу, кире кайтару; хакын-зарарын түләтү; 2. *биол.* өзелгән әгъзаларның яңадан үсүе).

**РЕСТОРА'Н** *м.*— ресторан.

**РЕСТОРА'ННЫЙ** — ресторандагы, ресторан...-ы; *ресторанный обед* — ресторандагы көндезге аш.

**РЕСТОРА'НЩИК** *м.*, **РЕСТОРАТЁР** *м.*, **РЕСТОРА'ТОР** *м. устар.*— ресторанчы, ресторан хуҗасы, ресторан тотучы.

**РЕСТОРА'ЦИЯ** *ж. книж. устар.*— ресторан.

**РЕСУ'РС** *м.*— ресурс (1. *чаще мн.* байлык, чыганак, запас, мөмкинлек; *природные ресурсы* — табигать байлыклары; *мобилизация всех ресурсов* — бөтен ресурсларны туплау; 2. *фин. экон.* акча запасы, доход чыганагы; *изыскать ресурсы для организации нового предприятия* — яңа предприятие оештыру өчен кирәкле ресурслар табу; 3. чара, таяныч, терәк, мөмкинлек; *последний ресурс* — соңгы чара; соңгы таяныч).

**РЕТИ'ВО** *нареч.*— тырышып, тырышлык белән, ихлас белән, күңел биреп; *ретиво работать* — тырышып (күңел биреп) эшләү.

**РЕТИВО'Й** *устар. нар.-поэт.*— к. ретивый.

**РЕТИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — тырышлык, гайрәтлелек.

**РЕТИ'ВЫЙ** *разг.*— 1. *(усердный)* тырыш, уңган; эшкә батыр, эшчән; җанын куеп эшли торган; *ретивый работник* — тырыш эшче; *ретивая пчела* — эшчән бал корты; 2. кызу, җилле, елдам, житез, ярсу; *ретивый конь* — ярсу ат; 3. шаян, шук, чая; *ретивые песни* — шаян җырлар. ◇ Ретивое *нар.-поэт.*, *в знач. сущ.* — шашкын йөрәк, ярсу йөрәк; *забилось ретивое* — ярсу йөрәк ашкынып тибә башлады.

**РЕТИ'НА** *ж. анат.*— ретина, күзнең челтәр катлавы.

**РЕТИНИ'Т** *м. мед.*— ретинит, күзнең челтәр катлавы ялкынсынуы (шешүе).

**РЕТИРА'Д** *м.*, **РЕТИРА'ДА** *ж. устар.*— 1. *воен. (отступление)* ретирада, чигенү, чигенеш; 2. *воен.* ретирада, ныгытма (крепость эчендә, чигенә калганда кереп бикләнә торган урын); 3. бәдрәф.

**РЕТИРОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов.*— 1. *устар.* чигенү; 2. *разг. ирон.* китү, китеп бару, күздән югалу, шылу, сызу, таю.

**РЕТО'РИКА, РЕТОРИ'ЧЕСКИЙ** — к. риторика, риторический.

**РЕТО'РСИЯ** *ж. мн.* нет, *полит.*— реторсия (экономик интересларны кысуга яки бозуга җавап рәвешендә бер дәүләтнең икенче дәүләткә тәэсир итү чаралары).

**РЕТО'РТА** *ж. хим. тех.*— реторта (кәкре муенлы шарсыман пыяла савыт; химия лабораторияләрендә кулланыла).

**РЕТРАНШЕМЕ'НТ** *м. воен.*— ретраншемент (крепость эчендәге ныгытма).

**РЕТРОГРА'Д** *м.*, **РЕТРОГРА'ДКА** *ж. устар.*— ретроград (прогресска каршы кеше, иске фикерле кеше; реакционер; кадимче).

**РЕТРОГРА'ДНЫЙ** *устар.*— реакцион, кара фикерле, искелекне яклаучы, прогресска каршы.

**РЕТРОСПЕКТИ'ВНЫЙ** *книж.*: **ретроспективный взгляд** — ретроспектив карау (мәсьәләнең тарихына күз салу, тарихын күзәтү); **ретроспективное освещение вопроса** — мәсьәләне ретроспектив яктырту (мәсьәләне хәзергедән үткәнгә таба тикшерү).

**РЕТУШЁВКА** *ж. мн.* нет, *спец.*— 1. *(действие)* к. ретушировать; 2. к. ретушь.

**РЕТУШЁР** *м.*— ретушёр, ретушьчы, ретушьлаучы (рәсемне, негативны буяп төзәтүче).

**РЕТУШИ'РОВАНИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— к. ретушировать.

**РЕТУШИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— ретушьлау, ретушьлап төзәтү (рәсемне, негативны буяп төзәтү).

**РЕТУШИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.*— ретушьлану.

**РЕ'ТУШЬ** *ж. мн.* нет— ретушь, ретушьлау (1. *фото.* фоторәсемне яки негативны буяп төзәтү; 2. *археол.* эш кораллары ясаганда ташны китеп эшкәртү).

**РЕФА'КЦИЯ** *ж. торг. ж.-д.*— рефакция, скидка, ташлама (1. тимер юл белән бик күп йөк җибәргәндә тариф бәясен киметү; 2. сәүдә эшендә товарның аварлыгы һәм бәясенә карата мәгълүм бер шартларда ясала торган киметүләр).

**РЕФЕРА'Т** *м.*— реферат (билгеле бер китап, гыйльми эш һәм теориянең төп куелышлары бәян ителеп язылган яки халык алдына чыгып сөйләнелә торган доклад).

**РЕФЕРА'ТНЫЙ** *книж.*— реферат формасындагы, реферат рәвешендәге.

**РЕФЕРЕ'НДУМ** *м. полит.*— референдум, гомумхалык фикерен сорау (бик әһәмиятле берәр мәсьәлә буенча закон чыгару өчен аны гомумхалык карамагына тавышка кую).

**РЕФЕРЕ'НТ** *м. книж.*— референт (1. реферат укучы; 2. мәгълүм бер төр мәсьәләләр буенча даими докладчы яки консультация бирүче белгеч).

**РЕФЕРЕ'НЦИЯ** *ж.*— референция (1. *офиц. спец.* к. рекомендация; 2. *торг. устар.* берәр шәхеснең кредит түләрлек мөмкинлеге булуы турында финанс учреждениесе тарафыннан бирелгән белешмә язуы).

**РЕ'ФЕРИ, РЕФЕРИ'** *м. нескл. спорт.*— судья, рефери (спорт ярышларында).

**РЕФЕРИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— 1. *книж.* реферат язу, реферат уку; ***реферировать книгу*** — китапка реферат язу (эчтәлеген һәм төп фикерләрен язып яки сөйләп чыгу); 2. *спорт.* рефери булу, судьялык итү (спорт ярышында).

**РЕФЕРИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. книж.*— реферат язылу, реферат укылу.

**РЕФЛЕ'КС** *м.*— 1. рефлекс (а. *физиол.* организмның тышкы тәэсиргә җавап реакциясе, тышкы ярсытудан хәрәкәтләнүе; ***условный рефлекс*** — шартлы рефлекс, организмның тормыш дәвамында казанган рефлексы; ***безусловный рефлекс*** — шартсыз рефлекс, тумыштан булган рефлекс; б. аңсыз, ихтыярсыз, машиналь хәрәкәт); 2. *перен. книж. (отражение, следствие)* берәр нәрсәнең нәтиҗәсе, чагылышы, тәэсире; 3. *живоп.* (рәсемдә, картинада) шәүлә, төсмер; ***рефлексы зелёной листвы на белой стене дома*** — өйнең ак стенасына агач яфракларыннан төшкән яшел шәүлә.

**РЕФЛЕКСИ'ВНЫЙ** — к. рефлективный.

**РЕФЛЕ'КСИЯ** *ж. мн.* нет — рефлексия (1. *физ.* предмет өстендә яктылык чагылышы; 2. *филос. псих.* уйлану, үз-үзен тикшерү, үз хисләреңне тикшерү, үз кичерешләреңә анализ ясау).

**РЕФЛЕ'КСНЫЙ**: **рефлексная схема** *радио* — рефлекслы схема (радиоалгыч элементларын лампа икеләтә эшләрлек итеп, ягъни югары һәм түбән ешлыкны көчәйтә торган итеп тоташтыру).

**РЕФЛЕКСО'ЛОГ** *м. книж.*— рефлексолог, рефлексология белгече.

**РЕФЛЕКСОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** *науч.*— рефлексология...-ы; рефлексология өлкәсендәге, рефлексология буенча...; рефлексологик; ***рефлексологические исследования*** — рефлексологик тикшеренүләр.

**РЕФЛЕКСОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет, *науч.*— рефлексология (рефлекслар турындагы фән).

**РЕФЛЕКТИ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *науч.*— рефлективлык, аңсыздан (ихтыярсыз, ирексез) эшләнү.

**РЕФЛЕКТИ'ВНЫЙ** *науч.*— рефлектив, ихтыярсыз, ирексез, аңсыз эшләнә торган, машиналь; ***рефлективные движения*** — рефлектив хәрәкәтләр.

**РЕФЛЕКТИ'РОВАТЬ** *несов.*— 1. *науч.* рефлекс (берәр хәрәкәт) белән җавап кайтару, тышкы тәэсиргә җавап бирү; 2. *книж.* уйлану, тирән уйга чуму, үз-үзен анализлау.

**РЕФЛЕКТОМЕ'ТР** *м. физ.*— рефлектометр (яктылык нурларының чагылу дәрәҗәсен — коэффициентын үлчәү приборы).

**РЕФЛЕ'КТОР** *м.*— рефле́ктор (1. *астр.* батынкы көзгеле телескоп; 2. *физ.* чагылдыргыч көзге — яктылык нурларын тиешле якка таба юнәлдерүче батынкы көзге).

**РЕФЛЕ'КТОРНЫЙ** *физ. астр.*— рефле́кторлы.

**РЕФЛЕКТО'РНЫЙ** *физиол. псих.*— рефлекто́р..., рефлекслы; ихтыярсыз (ирексездән, аңсыз) эшләнә торган; ***рефлекторное движение*** — рефлектор хәрәкәт.

**РЕФО'РМА** *ж.*— реформа (1. яңарту, үзгәртү, үзгәртеп кору; 2. *полит.* яшәп килә торган җәмгыять төзелешенең нигезләренә кагылмый торган кайбер төзәтүләр, үзгәрешләр, яңартулар, ислах).

**РЕФОРМА'ТОР** *м. книж.*— реформатор (үзгәртеп коручы, реформа үткәрүче; реформа ясаучы, ислахчы).

**РЕФОРМА'ТОРСКИЙ** *книж.*— реформатор(лык)...-ы; реформа ясау...-ы; ***реформаторские попытки*** — реформа ясау омтылышлары; реформаторлык омтылышлары

**РЕФОРМА'ТСКИЙ** — 1. *истор.* реформация...-ы; реформация чоры....-ы, реформация чорындагы; *реформатские войны* — реформация чоры сугышлары; 2. *церк.* реформат...-ы; *реформатская церковь* — реформат чиркәве (протестантларда).

**РЕФОРМА'ТСТВО** *ср. мн.* нет, *церк.* — реформатлык (реформатларның дини өйрәтүләре).

**РЕФОРМА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *истор.* — реформация (XVI йөздә Көнбатыш Европада феодализмга каршы юнәлдерелгән һәм католик диненә, папа хакимлегенә каршы дини көрәш төсен алган иҗтимагый-политик хәрәкәт).

**РЕФО'РМЕННЫЙ** *устар.* — реформа...-ы; *реформенный период* — реформа чоры.

**РЕФОРМИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *полит.* — реформизм (эшчеләр хәрәкәтендә булган оппортунистик агым; аның тарафдарлары, властьны буржуазия кулында калдыру өчен, капиталистик төзелешкә аз-маз реформалар ясауны гына яклап, революцион сыйнфый-политик көрәшне инкарь итеп чыгалар).

**РЕФОРМИ'РОВАТЬ** *сов* и *несов.* — үзгәртү, үзгәртеп кору, яңалыклар (үзгәрешләр) кертү, реформа үткәрү, реформа ясау.

**РЕФОРМИ'РОВАТЬСЯ** — 1. *сов.* и *несов.* үзгәрү (реформа нәтиҗәсендә); 2. *несов. страд.* реформа ясалу, үзгәртелү, үзгәртеп корылу.

**РЕФОРМИ'СТ** *м.*, **РЕФОРМИ'СТКА** *ж. полит.* — реформист(ка), реформизм тарафдары.

**РЕФОРМИ'СТСКИЙ** *полит.* — реформист...-ы; реформизм...-ы; реформистлар...-ы; реформистлык...-ы; *реформистская тактика* — реформистлык тактикасы.

**РЕФРАКТОМЕ'ТР** *м. физ.* — к. рефлектометр.

**РЕФРА'КТОР** *м. астр.* — рефрактор (нур сындыргыч линзалы телескоп).

**РЕФРА'КТОРНЫЙ** *астр.* — рефракторлы.

**РЕФРАКЦИО'ННЫЙ** *физ.* — рефракция(ләнү)...-ы, рефракцион; *рефракционный эквивалент* — рефракцияләнү эквиваленты (нур сындырыш эквиваленты).

**РЕФРА'КЦИЯ** *ж. мн.* нет — рефракция (1. *физ.* яктылык нурларының сынуы; 2. *астр.* җир атмосферасы аша үткәндә, яктылык нурларының сынуы аркасында, күк җисемнәренең урыннарыннан авышкан төсле күренүләре).

**РЕФРЕ'Н** *м. лит.* — рефрен, кушымта (шигырьдә һәм җырда билгеле бер тәртиптә кабатланып килә торган юл яки строфа).

**РЕФРИЖЕРА'ТОР** *м. тех.* — рефрижератор (1. холодильникларның сыекчаны парга әйләндереп, түбән температура бирә торган өлеше; 2. суыткычлы вагон, суыткычлы пароход — тиз бозылучан азык-төлекне ташу өчен кулланыла торган транспорт).

**РЕФРИЖЕРА'ТОРНЫЙ** *тех.* — рефрижераторлы, суыткычлы, холодильниклы; *рефрижераторное судно* — рефрижераторлы судно; *рефрижераторный вагон* — суыткычлы вагон.

**РЕФУЛЁР** *м. тех.* — рефулёр (су төбен тирәнәйтү механизмы, балчык суыргыч, землесос).

**РЕФУТА'ЦИЯ** *ж. устар.* — к. опровержение.

**РЕФЮ'Ж** *м. спец.* — рефюж (урамда трамвай тукталышы янында җәяүлеләр өчен ясалган мәйданчык).

**РЕХНУ'ТЬСЯ** *сов. простореч. пренебр.* — акылдан язу (шашу), акылсызлану, тилерү, исәрләнү.

**РЕЦЕНЗЕ'НТ** *м.* — 1. рецензент, рецензиянең авторы, рецензияләүче; 2. рецензияләр язучы, рецензия язу белән махсус шөгыльләнүче тәнкыйтьче.

**РЕЦЕНЗИ'РОВАНИЕ** *ср.* — рецензияләү, рецензия яз(дыр)у; *отдать статью на рецензирование* — мәкаләне рецензия(ләр)гә бирү.

**РЕЦЕНЗИ'РОВАТЬ** *несов.* — рецензияләү, рецензия язу.

**РЕЦЕНЗИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.* — рецензияләнү, рецензия язылу.

**РЕЦЕ'НЗИЯ** *ж.* — рецензия (язма һәм басма әсәргә, фәнни хезмәткә, шулай ук сәхнә тамашасына язма рәвештә кыскача бәя бирү; шундый бәя биреп язылган тәнкыйть мәкаләсе).

**РЕЦЕ'ПТ** *м.* — 1. рецепт (врачның авыруга дару хәзерләү турында аптека өчен язып биргән рәсми кәгазе); 2. *перен.* өйрәтү, күрсәтмә, рецепт (берәр ашамлык, эремә яки катнашма хәзерләү өчен, аның составын һәм хәзерләү рәвешен күрсәтеп язган язу); *пивоварный рецепт* — сыра кайнату рецепты; 3. *перен. разг.* алым, ысул, калып, рецепт; *поступать по готовому рецепту* — әзер калып буенча эш итү.

**РЕЦЕПТА'Р** *м. апт.* — рецептар (аптекада рецептлар кабул итеп торучы).

**РЕЦЕ'ПТОРЫ** *м. биол.* — рецепторлар (тышкы һәм эчке тирәлектән тәэсир алып торучы нерв очлары).

**РЕЦЕПТУ'РА** *ж. мн.* нет, *мед.* — рецептура (дару хәзерләү һәм дөрес рецепт язып бирү турындагы белем).

**РЕЦЕПТУ'РНЫЙ** *мед.* — рецептлар...-ы; рецептура...-ы; *рецептурная книга* — рецептлар китабы, рецептлар белешмәлеге.

**РЕЦЕ'ПЦИЯ** *ж. мн.* нет, *науч.* — рецепция, кабул итеп үзләштерелү (башка иҗтимагый шартларда барлыкка килгән җәмгыять һәм культура формаларын билгеле бер җәмгыятьнең кабул итеп үзләштерүе).

**РЕЦЕССИ'ВНЫЙ** *биол.* — рецессия (бетү, югалу)...-ы; *рецессивные признаки в организме* — организмда рецессия билгеләре.

**РЕЦЕ'ССИЯ** *ж. мн.* нет, *биол.* — рецессия (организмда нәселдән килгән кайбер билгеләрнең әкренләп бетә-югала бару күренеше).

**РЕЦИДИ'В** *м.* — рецидив (1. яңадан кабатлану, кабат барлыкка килү, яңадан килеп чыгу; 2. *мед.* беткәндәр дип уйланган авыруның кабатлануы, кабат кайтуы; 3. *юр.* җинаятьнең кабатлануы, яңадан эшләнүе).

**РЕЦИДИВИ'СТ** *м.*, **РЕЦИДИВИ'СТКА** *ж. право* — рецидивист, җинаятьне кабатлаучы (берничә тапкыр хөкем ителсә дә, һаман җинаять эшләүне дәвам иттерүче).

**РЕЦИПИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. науч.*— рецепцияләү, кабул итеп үзләштерү.

**РЕЦИПИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. науч.*— рецепцияләнү, кабул итеп үзләштерелү.

**РЕЦИТА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *книж.*— к. рецитировать.

**РЕЦИТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.*— декламация сөйләү, чыгып сөйләү, кычкырып уку (тыңлаучылар алдында).

**РЕЦИТИ'РОВАТЬСЯ** *несов. книж.*— декламация сөйләнү, чыгып укылу.

**РЕЧЕВО'Й** — сөйләү...-ы; сөйләм...-ы; *речевые такты* — сөйләм тактлары (паузадан паузага кадәр булган бүлекләр); *речевые навыки* — сөйләү күнекмәләре.

**РЕЧЕ'НИЕ** *ср. филол. устар.*— әйтем, әйтелмә, тәгъбир (ныгыган сүз тезмәсе); *в каждом языке много застывших речений* — һәрбер телдә бик күп катып калган сүз тезмәләре бар. ◇ **Слитное речение** — тезмә сүз (бер төшенчә белдерүче сүз тезмәләре, мәсәлән, „тимер юл" һ. б. ш. кебек).

**РЕЧИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *устар.*— күп сүзлелек, сүзчәнлек.

**РЕЧИ'ВЫЙ** *устар.*— күп сүзле, сүзчән.

**РЕЧИ'СТОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.*— телгә оста булу, сүзгә осталык, сүзчәнлек; күп сөйләүчәнлек.

**РЕЧИ'СТЫЙ** *разг.*— **1.** сүзгә (телгә) оста, бик матур (шәп) сөйли торган; **2.** *фам.* сүзчән, күп сүзле, күп сөйләүчән; *речистая старуха* — күп сөйләүчән карчык.

**РЕЧИТАТИ'В** *м. муз.*— речитатив, көйләп сөйләү (музыка әсәрләрендә сөйләшкән кебек җырлау).

**РЕ'ЧКА** *ж.*— елга, кечкенә елга, инеш; *горные речки* — тау елгалары.

**РЕЧНИ'К** *м. спец.*— елгачы (елга транспортында эшләүче).

**РЕЧНО'Й** — елга...-ы; су...-ы; *речное пароходство* — елга пароходчылыгы; *речной трамвай* — су трамвае.

**РЕЧЬ** *ж.*— **1.** сөйләшү (сәләте), тел, сөйләшә белү; *речь — один из признаков, отличающих человека от животных* — кешенең сөйләшә белүе аны хайваннардан аера торган билгеләрнең берсе; **2.** *лингв.* тел, сөйләм, сөйләү; *стихотворная речь* — шигырь теле, шигъри сөйләм; *образная (живая) речь* — тасвирлы (җанлы) тел, образлы сөйләм; *устная речь* — телдән сөйләү, сөйләү теле; *письменная речь* — язу теле, язма сөйләм; **3.** сөйләү, сөйләшү, сөйләнү, сүз, гәп, әңгәмә; *об этом речи не было* — бу турыда сүз булмады; *завести речь* — сүз башлау, сүз кузгату; *дружеские речи* — дусларча сөйләшеп утырулар, дусларча әңгәмә; *затруднённая речь* — бик авыр сөйләү; *восторженные речи* — сокланып сөйләүләр; **4.** *обл. (слух)* сүз, имешмимеш сүз, хәбәр; *речь идёт в народе* — халык арасында сүз таралган; **5.** речь, чыгыш, чыгып сөйләү, нотык; *выступить с приветственной речью* — тәбрикләү рече (сүзе) белән чыгу; *надгробная речь* — күмгәндә сөйләү; *речь прокурора* — прокурорның чыгышы. ◇ **Владеть речью** — сөйләшү, сөйләшә алу; теле ачылу (мәсәлән, баланың). **Дар речи** — **1.** сөйләшү (тел) сәләте; **2.** сүзчәнлек, телгә осталык, тел ачкычы, сүз куәсе. **Контекст речи** (смысл) — сүз сөреше. **Членораздельная речь** — бүленмәле (аерым авазлардан торган) сөйләм. **Части речи** *грам.* — сүз төркемнәре. **Об этом и речи нет** — бу турыда сөйләп тәторасы түгел. **Не о том речь** — эш (мәсьәлә) анда түгел. **Каков предмет речи?** — сүз ни турыда бара? **Двигательный центр речи** — сөйләү хәрәкәтләренең үзәге. **Слуховой центр речи** — сөйләмне ишетү үзәге.

**РЕША'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— чишелү (хәл ителү) мөмкинлеге.

**РЕША'ТЬ** *несов.*— к. решить.

**РЕША'ТЬСЯ** *несов.*— **1.** к. решиться; **2.** *страд. школьн.* чишелү, исәпләп чыгарылу, җавабы табылу; **3.** *страд. офиц.* хәл ителү, карар кылыну, карар бирелү. ◇ **Не решаться** — кыймау, базмау, тайчану, тайчанып тору.

**РЕША'ЮЩИЙ** — **1.** хәлиткеч, төп, нигез; *решающий момент* — хәлиткеч момент; *решающая победа* — хәлиткеч җиңү; *решающий аргумент* — төп дәлил; **2.** хәл итүче, хәл итә торган, чишә торган.

**РЕШЕ'НИЕ** *ср.*— **1.** *только ед.* к. решить 1, 2, 3, 4; *решение задачи подвигается медленно* — мәсьәләне чишү акрын бара; **2.** *школьн.* чишелеш; *эта задача имеет два решения* — бу мәсьәләнең ике чишелеше бар; **3.** карар, хөкем; *решение суда* — суд хөкеме; **4.** нәтиҗә, ният, уй, фикер, карар; *я пришёл к решению уехать* — мин китәргә дигән карарга килдем.

**РЕШЁННЫЙ** — хәл ителгән, үзгәрмәслек итеп куелган.

**РЕШЕ'ТИНА** *ж. плотн. тех.*— бәпкә өслеге, кайчы өслеге, шикмә тактасы (түбәне калай, такта белән ябу өчен бәпкәләр өстенә рәшәткәләп кагылып калдырыла торган тар, озын такта).

**РЕШЕ'ТИТЬ** *несов.*— **1.** *плотн.*, *тех.* (түбә ябу өчен) шикмәләр кагып чыгу; **2.** *разг.* к. изрешетить.

**РЕШЁТКА** *ж.*— **1.** рәшәткә; челтәрле (рәшәткәле) койма; *железная решётка* — тимер рәшәткә; **2.** *(колосники)* тимер челтәр, самовар рәшәткәсе, мич рәшәткәсе; **3.** *спец.* челтәр, челтәрле чигеш; **4.** *разг.* к. решка. ◇ **За решётку (посадить)** *разг.*— төрмәгә ябу, төрмәгә утырту, таш капчыкка салу. **За решёткой** — төрмәдә, ябылуда, тоткында.

**РЕШЕ'ТНИК** I *м. спец.*— шикмә, шикмәлек материал, бәпкә өслеге өчен материал (түбә япканда бәпкә өстенә кадаклана торган тар такталар).

**РЕШЕ'ТНИК** II *м. спец.*— иләкче, иләк ясаучы оста.

**РЕШЕТО'** *ср.*— иләк. ◇ **Черпать воду**

**решетом** — иләк белән су ташу (мәгънәсезгә эшләү, максатсыз эшләү). **Голова решетом (как решето)** — иләк баш, чүбек баш (онытучан кеше турында әйтелә). **Чудеса в решете** *ирон.*— күз күрмәгән, колак ишетмәгән (гаҗәп) нәрсәләр.

**РЕШЕ'ТЧАТЫЙ, РЕШЁТЧАТЫЙ** — 1. рәшәткә..., рәшәткәле, рәшәткәсыман; *решетчатый забор* — рәшәткәле койма; 2. челтәрле, челтәр-челтәр; *решетчатое окно* — челтәрле тәрәзә (тыштан тимер челтәр белән капланган тәрәзә). ◇ **Решетчатая кость** *анат.*— челтәр сөяк (умырткалы хайваннарның сеңерләр һәм нерв җепселләре үтә торган бик күп тишекле маңгай сөяге).

**РЕШИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет — тәвәккәллек, кыюлык, батырлык.

**РЕШИ'ТЕЛЬНО** *нареч.*— 1. кыю рәвештә, кискен төстә; *решительно вскрывать недостатки* — җитешсезлекләрне кыю рәвештә ачып салу; 2. тәвәккәллек (кыюлык, ныклык) белән, нык; тартынмыйча; *действовать решительно* — кыюлык белән эш итү; 3. катгый рәвештә, аяк терәп; *решительно потребовать* — катгый рәвештә таләп итү, аяк терәп таләп итү; 4. *разг.* чын-чынлап, тәмам, бөтенләй; *решительно развинтился* — тәмам бозылды; 5. өзеп, кырт кисеп; *решительно сказать* — өзеп әйтү; 6. ...да, ...да кал(дыр)мыйча; *решительно все* — барысы да, беркем дә калмыйча; *решительно всё* — барысын да, бернәрсәне дә калдырмыйча; *решительно каждый* — һәркем дә; 7. *в знач. усилит. частицы* бөтенләй, һич, һичбер, һич тә; һичничек; *решительно ничего не понял* — бөтенләй бер нәрсә аңламадым.

**РЕШИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — тәвәккәллек, йөрәклелек, кыюлык, батырлык; кискенлек, катгыйлык; тартынмаучанлык.

**РЕШИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. тәвәккәл, кыю, батыр, йөрәкле, базымчак; *решительный человек* — кыю кеше; 2. кискен, катгый, соңгы, ахыргы, өзеп...; *он не дал решительного ответа* — ул катгый җавап бирмәде; 3. каты, кискен, катгый, гадәттән тыш; *принять решительные меры* — каты чаралар күрү; *решительный тон* — катгый тон; 4. хәлиткеч, хәл итә торган; әһәмиятле, мөһим, иң кирәк; *решительный момент настал* — хәлиткеч вакыт җитте; *помощь подоспела в решительный момент* — ярдәм иң кирәк вакытта килеп җитте; 5. *разг.* һичшиксез, ачыктан-ачык, чынчыннан, чын мәгънәсендә; *это — решительный негодяй* — ул чын мәгънәсендә кабахәт (ул чиктән ашкан кабахәт).

**РЕШИ'ТЬ** *сов.*— 1. чишү, чыгару, җавабын табу; *ты решил задачу?* — син мәсьәләне чиштеңме? 2. *спец.* хәл итү, хәл кылу, чишү; *решить проблему* — проблеманы хәл итү, мәсьәләне хәл кылу; 3. карар бирү, карар кылу, карар чыгару; хөкем чыгару, хөкем итү; *суд решил в мою пользу* — суд минем файдама хөкем итте; *совещание решило приступить к постройке завода* — киңәшмә завод төзүгә керешергә дип карар чыгарды; 4. нәтиҗәгә (фикергә, карарга) килү, карар итү; ...-ырга булу; ...-макчы булу; ...-ырга уйлау, исәпләү, исәп итү; *я решил остаться здесь* — мин монда калырга булдым; 5. *простореч. вульг.* *(убить)* үтерү, эшен бетерү; 6. *простореч.* *(уничтожить)* бетерү, юкка чыгару.

**РЕШИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. *(о задаче)* чишелү, җавабы чыг(арыл)у, җавабы табылу; 2. хәл ителү, хәл кылыну; тәмамлану, бетү; *дело решится не в его пользу* — эш аның файдасына хәл ителмәс (аның файдасына бетмәс); 3. бер эшкә керешү, күңел беркетү; ...-ырга карар бирү, хәл итү; ...-асы итү; ...-макчы булу, ...-рга булу; *я решился уехать отсюда* — мин моннан китәргә булдым; 4. кыю, базу, тәвәккәлләү; тәвәккәллек итү, кыюлык итү, батыр(чы)лык җитү, кыюлык җитү, җөрьәт итү; *никто не решился отрицать этого* — беркемнең чыгып моны инкарь итәргә кыюлыгы җитмәде; 5. *простореч. обл.* коры калу, колак кагу, мәхрүм калу; ...-дан язу, ...-дан калу, ...-сыз калу; *решиться ума* — акылдан язу; *решиться имущества* — малыннан коры калу, малыннан колак кагу.

**РЕ'ШКА** *ж. простореч.*— иләк, иләк як (вак акчаның бәясе күрсәтелгән ягы). ◇ **Орёл или решка?** — күнме, иләкме? (акча чөеп уйнаганда әйтелә).

**РЕШО'ТКА** *ж.*— к. решётка.

**РЕШПЕ'КТ** *м.*— респект.

**РЕЩИ'** *сов.* и *несов. церк. книж., поэт. устар.*— сөйләү, әйтү.

**РЕЭВАКУАЦИО'ННЫЙ** *офиц.* — кире эвакуацияләү...-ы; яңадан кайтару...-ы; элекке урынына кайтару...-ы; реэвакуация...-ы; *реэвакуационная комиссия* — реэвакуация комиссиясе.

**РЕЭВАКУА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *офиц.*— реэвакуация (эвакуацияләнгән кешеләрне һ. б. элекке урыннарына кире кайтару).

**РЕЭВАКУИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. офиц.*— кире эвакуацияләү, реэвакуацияләү, эвакуацияләнгәннәрне кайтару, реэвакуация ясау, элекке урынына кайтару.

**РЕЭВАКУИ'РОВАТЬСЯ** *офиц.*— 1. *сов.* и *несов.*— эвакуациядән кайту, реэвакуация белән кайту, яңадан кайту; 2. *несов. страд.* эвакуациядән кайтарылу, реэвакуацияләнелү; реэвакуация ясалу (үткәрелү).

**РЕЭ'КСПО'РТ** *м. мн.* нет, *экон.*— реэкспорт (чит илдән китерелгән товарларны кире чыгару).

**РЕЭМИГРА'НТ** *м. офиц.*— эмиграциядән кайтучы, реэмигрант, иленә кире кайтучы, эмиграциядән кайткан кеше.

**РЕЭМИГРА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *офиц.*— реэмиграция, эмиграциядән кайт(ар)у.

**РЕЭМИГРИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. офиц.*— эмиграциядән кайту.

**РЕ'Я** *ж.*— к. рей.

**РЕ'ЯТЬ** *несов.*— 1. *(о птицах)* канат какмый очу, салмак кына очу; 2. *(о знамёнах и т. п.)* җилфердәү, җилфердәп тору (бару); агылу.

**РЖА** *ж. мн.* нет, *устар. обл.*— к. ржавчина.

**РЖА'ВЕТЬ** *несов.*— тутыгу, тутык каплау, тутык белән каплану; күгәрү.

**РЖА'ВЕЦ** *м. обл.*— тутыклы сазлык (тимер рудалы сазлык).

**РЖА'ВИТЬ** *несов.*— тутыктыру, күгәртү.

**РЖА'ВЛЕНИЕ** *ср. мн.* нет, *спец.*— к. ржаветь.

**РЖА'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет— тутыккanлык, тутык басканлык, тутыккан (күгәргән) булу.

**РЖА'ВЧИНА** *ж. мн.* нет — 1. тутык; *ржавчина ест железо* — тутык тимерне ашый; 2. *(на болотах)* саз тутыгы; 3. тутык, күгәрек, ашлык гөмбәсе (үсемлек авыруы).

**РЖА'ВЧИННИК** *м. бот.*— тутык гөмбәсе (үсемлекләрне каплап ала торган бик вак паразит гөмбә).

**РЖА'ВЧИННЫЕ** *мн. бот.*— тутык гөмбәләре семьялыгы (үсемлекләрдә була торган паразит гөмбәләрнең бер төркеме).

**РЖА'ВЫЙ** — 1. тутыккан, тутыгып беткән, тутык баскан, тутыклы, күгәргән; *ржавый гвоздь* — тутыгып беткән кадак; 2. *разг.* тутык төсле, коңгырт, кызгылт-көрән; *ржавый цвет* — кызгылт-көрән төс; 3. *разг.* тимер рудалы, тутыклы (сазлык суы).

**РЖАНЕ'Ц** *м. обл.*— 1. *(спорынья)* арыш анасы; 2. к. тимофеевка.

**РЖА'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. к. ржать; 2. кешнәгән тавыш.

**РЖА'НИЩЕ** *ср. с.-х.*— арыш камылы; урылган арыш басуы.

**РЖА'НКА** *ж.*— 1. *бот.* ржанка (арыш белән бодайның серкәләнүе нәтиҗәсендә килеп чыккан гибрид үсемлек); 2. *зоол.* ужым чыпчыгы (коңгырт-көрән каурыйлы кечкенә кош).

**РЖАНО'Й** — арыш...-ы; *ржаная мука* — арыш оны; *ржаное поле* — арыш басуы (ужым кыры).

**РЖАТЬ** *несов.*— 1. *(о лошадях)* кешнәү; 2. *перен. просторец. фам. неодобр. (о человеке)* кешнәү, бик каты кычкырып көлү.

**РЖИ'ЩЕ** *ср. с.-х.*— к. ржанище.

**РИ'ГА** I *ж.*— рига, ябык (өсте ябулы) ындыр, әвен (ашлык көлтәләрен киптереп сугу урыны); 2. *обл.* рига (сугылмаган игенне үлчәгәндә кулланыла торган берәмлек — чама белән биш мең көлтәгә тигез).

**РИ'ГА** II: **поехал в Ригу** *эвф. разг. фам. ирон.*— Касыймга китте („косыйм"га китте, ягъни „косарга китте„ урынына киная).

**РИ'ГЕЛЬ** *м. тех.*— аркылы әрлек, ригель (терәк итеп куела).

**РИГОРИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книжс.*— ригоризм (берәр принципны яисә әхлак кагыйдәләрен үтәүдә артык таләпчәнлек, артык кырыслык; ныклык, катылык).

**РИГОРИ'СТ** *м.*, **РИГОРИ'СТКА** *ж. книж.*— ригорист(ка), ригоризмга бирелгән кеше.

**РИГОРИСТИ'ЧЕСКИЙ, РИГОРИСТИ'ЧНЫЙ** *книж.*— ригористик, ригористларча...; *ригористический образ мыслей* — ригористларча фикер йөртү.

**РИГОРИСТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — ригористлык, ригористларча булу.

**РИДИКЮ'ЛЬ** *м.*— ридикюль, сумка (хатын-кызларның кечкенә генә кул сумкасы).

**РИ'ЗА** *ж.*— ри́за (1. *церк.* попларның гыйбадәт вакытында кия торган өс киеме; 2. *истор.* патша киеме, патша япанчасы; 3. *устар. поэт.* кием, өс киеме; 4. *церк.* икона челтәре). ◇ **Разодрать на себе ризы** — кайгыдан өзгәләнү. **До положения риз** — 1. лаякыл булганчы, сәрхүш булганчы (эчү, эчерү); 2. *перен.* чиктән тыш, тәмам.

**РИ'ЗНИЦА** *ж. церк.*— ризница (чиркәүдә гыйбадәт әйберләре — киемнәре саклана торган бүлмә).

**РИ'ЗНИЧИЙ** *м. церк.* — ризничий (чиркәү әйберләренә мөдирлек итүче).

**РИК** *м.* — рик (район башкарма комитеты).

**РИКОШЕ'Т** *м. мн.* нет — рикошет, рикошет ясау (снаряд, пуля һ. б. ш. кебекләрнең берәр нәрсәгә бәрелеп, кыек почмак белән чагылуы); ◇ **рикошетом** —1. рикошет ясап; *пуля попала в него рикошетом*— пуля, рикошет ясап, аңа килеп тиде; 2. *разг. перен. шутл.* кеше гаебе өчен, кеше өчен; *он пострадал рикошетом* — ул кеше гаебе өчен бәлагә эләкте (ак эт бәласе кара эткә тиде).

**РИКОШЕТИ'РОВАТЬ** *несов. спец.* — рикошет ясау, рикошет ясап читкә китү (читкә сикерү).

**РИКОШЕ'ТНЫЙ** *спец.* — рикошет ясап тигән, рикошет ясап килеп тигән; *рикошетный удар* — рикошет ясап тию.

**РИ'КША** *м.* — рикша (ике тәгәрмәчле кечкенә арбага җигелеп, пассажир йөртүче кеше — Японияда һәм элекке Кытайда); *использование рикш — унизительная форма эксплуатации человека* — рикшалар хезмәтеннән файдалану — кешене эксплуатацияләүнең иң кимсеткеч формасы.

**РИ'МЛЯНИН** *м.*, **РИ'МЛЯНКА** *ж.*— римлы (1. *истор.* борынгы Рим дәүләте гражданы; 2. Рим гражданы, хәзерге Рим шәһәрендә яшәүче кеше).

**РИМСКИЙ** — Рим...-ы; *римский народ* — Рим халкы. ◇ **Римская церковь** — католик чиркәве; **Римский папа** — Рим папасы (католик диненең башлыгы). **Римские цифры** — Рим цифрлары: I, II, III, IV һ. б. ш. **Римское право** — Рим хокукы (борынгы Рим дәүләтенең законнар җыентыгы). **Римская свеча** — фейерверк.

**РИНГ** I *м.* — ринг (капиталистик илләрдә бизнесменнарның, зур табыш алу өчен, базардагы барлык товарларны сатып алып һәм складта тотып, бәяләрне күтәрү турындагы вакытлы килешүләре).

**РИНГ** II *м. спорт.* — ринг, бокс мәйданы.

**РИНК** *м. спорт.* — ринк (1. конькида йөрү өчен ясалма боз белән капланган махсус мәйдан; шундый мәйданы булган спорт бинасы; 2. тәгәрмәчле конькида йөрү өчен такта яки асфальт җәелгән махсус мәйдан).

**РИНОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** *мед.* — ринологик,

ринология...-ы; *ринологическая кафедра* — ринология кафедрасы.

**РИНОЛО'ГИЯ** *ж. мед.* — ринология (медицинаның борын авыруларын өйрәнә торган бүлеге).

**РИНОПЛА'СТИКА** *ж. мн.* нет, *мед.* — ринопластика (зарарланган борынны тәннең башка урыныннан тире-ит кисеп алып ямау).

**РИНОПЛАСТИ'ЧЕСКИЙ** *мед.* — ринопластика...-ы; ринопластик; *ринопластическая операция* — ринопластик операция.

**РИНОСКО'П** *м. мед.* — риноскоп, борын көзгесе (медицинада борын-тамак куышлыгын карау өчен кулланыла торган махсус көзге).

**РИНОСКОПИ'Я** *ж. мед.* — риноскопия, риноскоп белән карау (борын-тамак куышлыгын тикшерү).

**РИ'НУТЬСЯ** *сов. книж.* — кинәт кузгалып китү, чабып китү; кинәт ташлану, атылу; ябырылу, ыргылу.

**РИПС** *м.* — к. репс.

**РИС** *м. мн.* нет — дөге, дөге ярмасы.

**РИСК** *м. мн.* нет — 1. тәвәккәллек; кыюлык, батырчылык; *риск — благородное дело* — тәвәккәллек яхшы нәрсә; 2. мөмкин булган куркынычлык, хәвеф; *с риском для себя* — үз тормышын куркыныч астына куеп; 3. *спец. торг.* (сәүдә эшендә мөмкин булган) зыян, зарар; уңышсызлык, каза; *делить риск пополам* — (сәүдәдә) күргән зарарны уртак күтәрү. ◇ **На свой страх и риск** (действовать) — бөтен җаваплылыкны (бәла-казаны) үз өстенә алып (эш итү).

**РИСКНУ'ТЬ** *сов.* — 1. к. рисковать; 2. кыюлык (тәвәккәллек, батырчылык) җитү; базу, кыю, җөрьәт итү; *рискнул спросить его об этом* — аңардан бу турыда сорарга батырчылыгым җитте.

**РИСКО'ВАННЫЙ** — 1. тәвәккәлле, бик кыю, куркынычлы, хәвефле, хәтәр; тәвәккәллек сорый торган; *рискованный шаг* — куркынычлы адым; 2. *перен.* бик үк әдәпле булмаган, ике төрле аңлашылуы мөмкин булган; *рискованное выражение* — ике төрле аңлашылуы мөмкин булган тәгъбир.

**РИСКОВА'ТЬ** *несов.* — 1. тәвәккәлләү, тәвәккәллек күрсәтү, батырчылык итү; *если хотите добиться успеха, необходимо рисковать* — уңыш казанырга телисез икән — тәвәккәллек күрсәтергә кирәк; 2. куркыныч астына кую; *рисковать жизнью* — тормышны куркыныч астына кую; 3. мөмкин (ихтимал) булу; *вы рискуете опоздать* — сезнең соңга калуыгыз мөмкин (соңга калуыгыз бар).

**РИСКОВО'Й** *разг. торг.* — тәвәккәлләүгә нигезләнгән, тәвәккәлгә исәпләнгән, бәхетле очраклылыкка исәп тотылган (булса була, булмаса юк, дип эшләнгән); *пари является формой рискового договора* — пари тәвәккәлләүгә нигезләнгән килешүнең бер төре ул.

**РИСКО'ВЫЙ** *простореч.* — 1. к. рискованный; 2. *(очень смелый)* тәвәккәл, бик батыр, бик кыю, йөрәкле.

**РИ'СЛИНГ** *м.* — рислинг (виноград төре һәм шуннан ясалган эчемлек).

**РИСОВА'ЛЬНЫЙ** — рәсем (сурәт ясау)...-ы; *рисовальная бумага* — рәсем кәгазе.

**РИСОВА'ЛЬЩИК** *м.*, **РИСОВА'ЛЬЩИЦА** *ж. спец.* — 1. каләм (яки карандаш) белән рәсем ясаучы, бизәк төшерүче, үрнәк бизәк ясаучы (туку эшендә бизәкләү белгече); 2. рәсемче-художник, яхшы рәсемче; 3. *(любитель рисовать)* рәсем ясарга яратучы, һәвәскәр рәсемче.

**РИСОВА'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. к. рисовать; 2. рәсем, рәсем дәресе; *учитель рисования* — рәсем укытучысы.

**РИСОВА'ТЬ** *несов.* — 1. рәсем төшерү, бизәк төшерү, бизәкләү, рәсем ясау; рәсем ясау белән шөгыльләнү; *он рисует с 6 лет* — ул алты яшьтән рәсем ясау белән шөгыльләнә; 2. *перен.* тасвирлау, тасвир итү, сурәтләү, сурәтләп күрсәтү; *Островский в своих комедиях рисует быт купечества* — Островский үзенең комедияләрендә купецлар тормышын тасвирлый. ◇ **Рисовать всё в ярких красках** *перен.* — барысын да ал да гөл итеп күз алдына китерү.

**РИСОВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *страд.* рәсемгә алыну, рәсем (сурәт) ясалу, (рәсем, бизәк) төшерелү; сурәтләнү, тасвир ителү; *контуры картины сначала рисуются на полотне карандашом или углем* — картинаның төп сызыклары башта киндергә кара карандаш яки күмер белән төшерелә; 2. күренү, күренеп тору, сызылып күренү; *на горизонте рисуются зубцы гор* — офыкта тауларның очлы башлары сызылып күренә; 3. *перен.* ...булып тоелу, күз алдына килү; *жизнь рисовалась ему сплошным праздником* — тормыш аңа тоташ бәйрәм булып тоела иде; 4. кылану, кыланчыклану, боргалану-сыргалану; *она слишком рисуется* — ул артык кыланчыклана.

**РИСО'ВКА** *ж. мн.* нет — к. рисоваться 4.

**РИСОВО'ДСТВО** *ср. мн.* нет, *с.-х.* — дөге игү, дөге игүчелек.

**РИСОВО'ДЧЕСКИЙ** *с.-х.* — дөгечелек...-ы; дөге игү белән шөгыльләнүче; *рисоводческие совхозы* — дөгечелек совхозлары.

**РИ'СОВЫЙ** — дөге...-ы; дөге ярмасыннан хәзерләнгән; *рисовое поле* — дөге кыры; *рисовая каша* — дөге боткасы.

**РИСОСЕ'ЯНИЕ** *ср. спец.* — дөге игү, дөге чәчү.

**РИСТА'ЛИЩЕ** *ср. книж. торж. устар.* — ярыш мәйданы, чабыш мәйданы; ярыш, бәйге, чабыш; *конные ристалища* — ат чабышлары.

**РИСТА'НИЕ** *ср. книж. устар.* — бәйге, чабыш(у), ярыш(у), ат чабышы, атта йөрү ярышлары.

**РИСУ'НОК** *м.* — 1. рәсем, сурәт; бизәк; картинка; *карандашный рисунок* — карандаш белән ясалган рәсем; 2. *спец.* картинаның төп сызыклары, контуры; *этот художник мастер рисунка* — бу художник картинаның төп сызыкларын (рәсемен) оста бирә; 3. *перен.* сызык, сызымта, контур;

*рисунок гор на горизонте* — офыктагы тау сызыклары (контурлары).

**РИСУ'НЧАТЫЙ** *спец.* — бизәкле, парчалы; *рисунчатая ткань* — бизәкле тукыма.

**РИТМ** *м.* — ритм (1. тәртипле чиратлашу, кабатланып килү; җайга салынганлык; *ритм работы* — эш ритмы; *ритм движений* — хәрәкәт ритмы, хәрәкәтләрнең тәртипле кабатланышы; 2. музыкада — музыка элементларының, мәсәлән, үлчәү, көй, гармония һ. б. вакыт агышнан мәгълүм бер тәртиптә төзелүе; 3. *поэт.* шигырьдә билгеле бер тигез үлчәүлелек, ягъни сөйләм берәмлекләренең, мәсәлән, басымлы һәм басымсыз иҗекләрнең мәгълүм бер тәртиптә тигез чиратлашып килүләре; вәзен).

**РИТМИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — ритмлаштыру, ритм(лылык) кертү; *ритмизация движений* — хәрәкәтләрне ритмлаштыру.

**РИТМИЗО'ВАННЫЙ** — к. ритмический 1.

**РИ'ТМИКА** *ж.* — ритмика (1. *лит.* ритмнар, вәзеннәр системасы; ритмнар турындагы белем; 2. музыкага кушылып башкарыла торган ритмик хәрәкәтләр).

**РИТМИ'ЧЕСКИЙ** — 1. ритмик, ритмлы; тәртипле кабатлана торган, тигез үлчәүле; *ритмическая гимнастика* — ритмик гимнастика; *ритмические движения* — ритмлы хәрәкәтләр; 2. *лит.* ритмика (ритмнар системасы) турындагы; *ритмические исследования* — ритмика турындагы тикшеренүләр.

**РИТМИ'ЧНО** *нареч.* — бер ритмда, бертигез ритм белән; салмак кына, тигез генә, тәртипле рәвештә; *работать весь месяц ритмично* — ай буе бертигез ритм белән эшләү.

**РИТМИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — ритмлылык, ритмлы булу; ритм сакланган булу, тәртиплелек, салмаклык.

**РИТМИ'ЧНЫЙ** — к. ритмический 1.

**РИТМОПЛА'СТИКА** *ж. спец.* — ритмопластика, ритмик гимнастика (ритмлы хәрәкәт күнегүләре системасы).

**РИТМОПЛАСТИ'ЧЕСКИЙ** *спец.* — ритмопластик, ритмлы хәрәкәтләр ясау...-ы; *ритмопластические упражнения* — ритмик хәрәкәтләр ясау күнегүләре.

**РИ'ТОР** *м.* — ритор (1. *истор.* борынгы Грециядә ораторлыкка өйрәтүче, риторика укытучысы; 2. *книж. неодобр.* матур, кабарынкы, ләкин сай эчтәлекле речь сөйләүче; 3. *устар.* элекке Россиядә духовный семинариядә риторика классы укучысы).

**РИТО'РИКА** *ж. мн.* нет — риторика (1. *науч.* ораторлык сәнгате теориясе; 2. *перен. книж. неодобр.* төче сүзләр, купшы сүзләр, күпертелгән, ләкин сай эчтәлекле сүзләр; 3. элекке Россиядә духовный семинарияләрнең түбән классы).

**РИТОРИ'ЧЕСКИЙ** — 1. риторик, риторика...-ы; риторикага караган, риторикага нигезләнгән; *риторический приём* — риторик алым; *риторические украшения речи* — сөйләмнең риторик бизәкләре; 2. *перен.* купшы, күпертелгән. ◇ **Риторический вопрос** — риторик сорау, җавабы үзендә булган сорау (ораторлар сөйләмендә — сорау рәвешендә раслау).

**РИТОРИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — артык риториклык, артык купшы (күпертмә) стильдә булу.

**РИТОРИ'ЧНЫЙ** *книж.* — к. риторический 2.

**РИ'ТОРСКИЙ** *книж. устар.* — риторлык...-ы; ораторлык...-ы; *риторский приём* — риторлык (ораторлык) алымы.

**РИ'ТОРСТВО** *ср. мн.* нет, *книж. устар.* — риторлык сәнгате (эчтәлегенә тирән кермичә оста, купшы сөйләү сәләте).

**РИ'ТОРСТВОВАТЬ** *несов. книж. устар.* — оста (матур итеп) сөйләү; күпертеп (купшы) сөйләү, риторик алымнар кулланып сөйләү.

**РИТУА'Л** *м. книж.* — ритуал (1. *церк.* дини йолалар; *ритуал погребения* — мәет күмү йолалары; 2. *офиц.* церемония, тәртип-кагыйдәләр; *ритуал приёма послов* — илчеләрне кабул итү ритуалы).

**РИТУА'ЛЬНЫЙ** *книж.* — ритуаль, дини йола буенча үткәрелә торган.

**РИТУРНЕ'ЛЬ** *м. муз.* — ритурнель (1. аккомпанементның кушымта рәвешендә кабатлана торган өлеше; 2. танец алдыннан башкарыла торган кечкенә музыкаль кереш).

**РИФ** I *м.* — риф, кыяташ (су астында яисә су өсте тигезлегендә була торган, диңгездә корабльләр йөрү өчен куркынычлы кыя ташлар).

**РИФ** II *м. мор.* — риф (җилкәндә — бау үткәреп җилкәнне тарттыру һәм аның өс йөзен кечерәйтү өчен хезмәт итә торган элмәк яки тишек). ◇ **Брать рифы** — җилкән бауларын тарту (көчле җил чыкканда җилкәнне кечерәйтү өчен).

**РИФЛЕ'НИЕ** *ср. тех.* — сырлау, сырлап эшкәртү, кытыршыландыру (детальнең өс йөзенә кытыршылык бирү өчен төрле ысул белән эшкәртү).

**РИФЛЁНЫЙ** I *мор.* — тартып кечерәйтелгән (җилкән).

**РИФЛЁНЫЙ** II *тех.* — сырлы, сырлы-сырлы, сырлап эшкәртелгән; кытыршы; шакмак-шакмак итеп сырланган; *рифлёное железо* — сырлап эшкәртелгән тимер плита.

**РИ'ФМА** *ж. лит.* — рифма (шигырь юлларындагы соңгы сүзләрнең әйтелеше аваздаш булу; кафия). ◇ **Мужская рифма** — басым соңгы иҗеккә төшкән рифма.

**РИФМА'Ч** *м. разг. презрит.* — рифмач, начар шагыйрь.

**РИФМО'ВАННЫЙ** — рифмалы, рифмалашкан, рифмага салынган; рифмадаш, рифмалашып килгән.

**РИФМОВА'ТЬ** *несов.* — 1. *лит.* рифмалашу, рифмалашып килү, рифмадаш булу; *эти слова рифмуют между собой* — бу сүзләр бер-берсе белән рифмалашып киләләр; 2. *лит.* рифмала(штыр)у, рифмага салу, рифма итеп китерү; 3. *шутл.* рифма үрү, рифма тезү (шигырь языштыру).

**РИФМОВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. рифмо-

вать 1; 2. *страд.* рифмалану, рифмага салыну, рифмалаштырылу.

**РИФМО'ВКА** *ж. лит.* — рифмалашу, рифмаланыш (шигырьдә рифмаларның чиратлашып килү тәртибе); *вольная рифмовка* — ирекле рифмаланыш.

**РИФМОПЛЁТ** *м. разг. презрит.* — рифма үрүче (начар шигырьләр язучы).

**РИФМОПЛЁТСТВО** *ср. мн.* нет, *разг. презрит.* — рифмачылык, рифма үрү, рифма тезү белән маташу; начар шигырь язу.

**РИХТОВА'ЛЬНЫЙ** *тех.* — төзәтү (турайту, турылау)...-ы; *рихтовальный прибор* — турылау коралы.

**РИХТОВА'ТЬ** *несов. тех.* — төзәйтү, турайту, турылау.

**РИХТОВА'ТЬСЯ** *несов. страд. тех.* — төзәйтелү, турайтылу, турайтып куелу.

**РИХТО'ВКА** *ж. тех.* — к. рихтовать; *рихтовка пути* — юлны турылау.

**РИЦИ'Н** *м.*, **РИЦИ'НКА** *ж. бот.* — к. клещевина.

**РИЦИ'НОВЫЙ: рициновое масло** *мед. тех.* — кастор мае.

**РИЦО'ВКА** *ж. спец.* — рицовка ясау (китап тышлау эшендә катыргыны бөгү өчен үтмәс пычак белән сызу).

**РККА** (Рабоче-Крестьянская Красная Армия) *истор.* — РККА (Эшче-Крестьян Кызыл Армиясе).

**РКП(б): Российская Коммунистическая Партия (большевиков)** — РКП(б): Россия Коммунистлар (большевиклар) партиясе (Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең VII съездыннан XIV съездынача булган дәвердәге атамасы).

**РО'БА** *ж. старин. мор.* — роба, күлмәк, кием.

**РОБЕ'ТЬ** *несов.* — курку, шүрләү, кыймау; каушау; *не робей!* — курыкма (шүрләмә)!

**РОБИНЗОНА'ДА** *ж.* — робинзонада (1. *лит.* Д. Дефоның „Робинзон Крузо" әсәренә ияреп язылган мажаралы әдәби әсәрләр; гомумән, мажаралы сюжет; 2. мажаралар тезмәсе, бик күп мажаралар кичерү; бик күп каршылыкларны җиңеп чыгу; *проделать робинзонаду* — бик күп мажаралар кичерү; 3. *экон. ирон.* кешелек җәмгыяте Робинзон кебек япа-ялгыз бер кешенең хуҗалыгыннан башланып киткән, дигән вак буржуаз экономик теорияләргә Маркс тарафыннан көлеп бирелгән кушамат).

**РО'БКИЙ** — куркак, кыюсыз, куркучан; йөрәксез, юаш, басынкы; тартынчак; *робкий ребёнок* — юаш (басынкы) бала; *робкий взгляд* — кыюсыз караш. ◇ **Не робкого десятка** — (ул) куркаклардан түгел.

**РО'БКО** *нареч.* — куркып, шүрләп; кыюсызланып, тартынып; курка-курка, юаш кына, кыймыйча, кыюсызлык белән; *робко смотреть* — тартынып кына карау, кыймыйча гына карау.

**РО'БОСТЬ** *ж. мн.* нет — курку, кыймау, базмау; кыюсызлык, куркаклык, йөрәксезлек; тартынучанлык, юашлык, басынкылык.

**РО'БОТ** *м.* — робот (кеше хезмәтен хәтерләтә торган катлаулы эшләр башкаручы автомат).

**РОБРО'Н** *м. устар.* — роброн (киң, түгәрәк шлейфлы хатын-кыз күлмәге).

**РОБУРИ'Т** *м. тех.* — робурит (башлыча селитрадан гыйбарәт булган шартлаткыч матдә).

**РОВ** *м.* — тирән канау, тирән озын чокыр; *крепостной ров* — крепость тирәли канау; *противотанковые рвы* — танкка каршы казылган чокырлар.

**РОВЕ'СНИК** *м.*, **РОВЕ'СНИЦА** *ж.* — яшьтәш, кордаш.

**РОВНЕ'НИЕ** *простореч.* — к. равнение.

**РОВНЁХОНЬКИЙ** *простореч.* — бик тигез, тип-тигез, тап-такыр, шоп-шома.

**РОВНЁХОНЬКО** *нареч. простореч.* — 1. тигез генә, тип-тигез итеп, тап-такыр итеп; бик шома итеп; туп-туры, төп-төз; 2. к. ровно 1, 2, 3.

**РОВНЁШЕНЬКИЙ** *простореч.* — к. ровнёхонький.

**РОВНЁШЕНЬКО, РОВНЁШЕНЬКИ** *нареч. простореч.* — к. ровнёхонько.

**РОВНИ'ТЕЛЬ** *м. тех.* — тигезләгеч (кәгазь ясау машинасының бер детале).

**РО'ВНИ'ЦА** *ж. тех.* — (кабат эшкәртү өчен) тупас эрләнгән җеп, катмаган калын җеп.

**РО'ВНИ'ЧНЫЙ: ровничная машина** *тех.* — к. банкаброш.

**РО'ВНО** *нареч.* — 1. төз генә, туры гына, бертигез, салмак кына, тигез итеп; 2. нәкъ; төгәл, төп-төгәл; *он пришёл ровно в два часа* — ул төгәл сәгать икедә килде; 3. *разг.* бөтенләй, тәмам, һич, һичбер, берни дә; *он ровно ничего не понял* — ул һичбер нәрсә анламаган; 4. *простореч.* гүя... кебек, сыман; *ровно плачущий ребёнок, запищал где-то сыч* — гүя бала елаган кебек, кайдадыр ябалак чыелдый башлады; 5. шикелле, бугай;...-гандай...; *я его ровно где-то видел* — мин аны кайдадыр күргәндәй булам, мин аны кайдадыр күрдем шикелле.

**РО'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. тигезлек, такырлык; 2. төзлек, турылык; 3. салмаклык, бертигезлек, төгәллек; 4. тынычлык, сабырлык, тигез холыклылык; даимилек; 5. бердәйлек, тәнгәллек, тигез зурлыклылык.

**РОВНОТА'** *ж. мн.* нет — к. ровность.

**РО'ВНЫЙ** — 1. тигез, такыр, шома; тип-тигез; *ровная дорога* — тигез юл; *ровная местность* — тигез җир; 2. төз, туры, тигез сызылган; *ровная черта* — туры сызык; 3. тигез эрләнгән; *ровная пряжа* — тигез (төерсез) эрләнгән җеп; 4. салмак, бертигез, төгәл; *сильный, ровный ветер* — көчле, салмак җил; *ровный ход часов* — сәгатьнең төгәл йөрүе; 5. *перен. разг.* тыныч, тын; тигез, сабыр (холыклы); *ровный характер* — сабыр холыклы кеше; *ровная жизнь* — тыныч тормыш; 6. бердәй, бертигез; бертөрле, тигез зурлыктагы; тәнгәл (тиң, бәрабәр) килә торган; *ровная доля* — бертигез өлеш. ◇ **Ровный счёт** — түгәрәкләп исәпләү (вак-төякне исәпкә алмыйча). **Ровным счётом ничего** *разг.* — берни дә,

һичбер нәрсә, бөтенләй бернәрсә; *он ровным счётом ничего не знает* — ул бөтенләй бернәрсә белми. **Не ровен (не ровён) час** — к. неровный. **Ровный бег лошади** — атның җай(лы) гына юыртуы. **Ровная погода** — тотрыклы һава, даими һава.

**РО'ВНЯ** *м.* и *ж.* — тиң, тиңдәш, иш, үз ише, замандаш; *он ей не ровня* — ул аңа тиң түгел.

**РОВНЯ'ТЬ** *несов.* — тигезләү, такырайту, шомарту; турылау, төзәйтү; *ровнять землю* — җирне такырайту; *ровнять дорогу* — юлны турылау; *ровнять строй* — сафны тигезләү.

**РОВНЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. тигезләнү, шомару, такыраю; 2. *страд.* тигезләп куелу, шомартылу, такырайтылу; 3. *воен.* сафта тигезләнү; 4. *перен.* үрнәк алу, тиңләшү, тигезләнү, тигезләшеп бару (килү); *ровняться по передовикам* — алдынгылар белән тиңләшү.

**РОГ** *м. (мн. рогá)* — 1. мөгез; *оленьи рога* — болан мөгезе; 2. быргы, труба; *пастуший рог* — көтүче быргысы; *трубить в рог* — быргы кычкырту (сигнал бирү); 3. *перен.* япь, чыгынты; *рог наковальни* — сандал чыгынтысы; *якорные рога* — якорь япьләре; 4. *перен. разг. шутл.* (бәрелүдән чыккан) шеш, кабарынкылык, „мөгез"; 5. *разг.* тармак, борын, чыгынты; очлаеп торган җир, почмак; *рог хребта* — тау сыртының чыгынтысы; *рог скирда* — эскертнең почмагы; 6. *спец.* тәкә мөгезенә охшатып эшләнгән бизәк; 7. *разг.* мөгездән ясалган тәмәке савыты, дары савыты һ. б. ◇ **Наставить (носить) рога** *разг. устар.* — мөгез кую, мөгез утырту, мөгезле булу (хатынның иренә хыянәт итүенә ишарә). **Рог изобилия** — муллык символы, муллык билгесе (чәчәк-җимешләр белән тулы мөгез рәсеме). **Как из рога изобилия** *книж.* — янгыр кебек (ява, явып тора), исәпсез (килеп тора), бетмәстөкәнмәс. **Обломать (сломать) рога** (*кому*) *разг. перен.* — кикриген шиңдерү, мөгезен сындыру, гайрәтен чигерү (тыйнаграк, юашрак итү). **Брать быка за рога** *разг.* — үгезне мөгезеннән эләктерү (вакытны суздырмыйча турыдан-туры төп мәсьәлә буенча ныклап эшкә керешү). **Согнуть в бараний рог** *кого-н. разг.* — берәүне бөгеп салу, кырыкка бөгү (каты куллылык белән буйсындыру).

**РОГА'ЛЬ** *м. обл.* — сука башы, сука тоткасы.

**РОГА'СТЫЙ** — зур мөгезле; *рогастый бык* — зур мөгезле үгез.

**РОГА'ТЕТЬ** *несов. обл.* — мөгез чыг(ар)у, мөгез үс(тер)ү.

**РОГА'ТИК** *м. разг. обл. шутл.* — 1. мөгезле җәнлек; 2. мөгезле коңгыз (мөгезсыман үсентеле бөҗәк).

**РОГА'ТИНА** *ж. охот.* — ау сөңгесе, сөңгеле күсәк (аю аулау өчен очына үткен сөңге куелган күсәк).

**РОГА'ТКА** *ж.* — 1. *воен.* рогатка; *противотанковые рогатки* — танкка каршы рогаткалар; 2. киртә, тоткарлама (аркылыторкылы беркетелгән казыклардан гыйбарәт тоткарлау җайланмасы); *поставили рогатку на дороге* — юлга тоткарлама куйганнар, юлны киртәләгәннәр; 3. *перен.* тоткарлык, тоткарлау; киртә, каршылык; *цензурные рогатки* — цензура тоткарлыклары, цензура киртәләре; 4. рогатка, аткыч (ике япьле чыбыкка резинка бәйләп ясалган уенчык); *мальчишки бьют из рогаток* — малайлар рогаткадан аталар; 5. *обл.* гөбе таягы, атлавыч; 6. *обл.* җәпле муендырык (терлекләргә бакчага кермәсен өчен кидерелә торган камытчык).

**РОГА'ТЫЙ** — 1. мөгезле; *(крупный) рогатый скот* — мөгезле (эре) терлек; 2. мөгезсыман, ураксыман, дагасыман; *рогатый месяц* — ураксыман ай; 3. *разг. фам. устар.* хатыны хыянәт итә торган ир.

**РОГА'Ч** I *м. зоол.* — мөгезләч, мөгезле коңгыз.

**РОГА'Ч** II *м. зоол.* — ата болан (яки мөгезле башка хайван).

**РОГА'Ч** III *м. обл.* — 1. зур ухват, чуен тоткыч; 2. (гомумән) япьле нәрсә, эләктергеч; 3. *пожарн.* янгын сәнәге (янгында бүрәнәләрне ишү өчен).

**РОГА'Ч** IV *м. шутл.* — к. рогоносец.

**РОГОВИ'ДНЫЙ** *книж.* — мөгезсыман; *роговидный слой* — мөгезсыман катлау.

**РОГОВИ'К** *м. мин.* — мөгезташ, роговик (кварц, кыр шпаты, слюда һ. б. минераллар кушылмасыннан гыйбарәт каты тау токымы — кератит).

**РОГОВИ'НА** *ж. спец.* — мөгез эзе (эшкәртелә торган тиренең уң ягында сөзүдән ертылган яки сыдырылган урын).

**РОГОВИ'ЦА** *ж. анат.* — мөгез катлау, мөгез пәрдә (күзнең үтә күренмәле өске тышчасы).

**РОГОВО'Й** — 1. мөгез...; мөгездән эшләнгән; *роговое вещество* — мөгез матдә (чәч, мөгез, тырнакларны тәшкил итә торган матдә); *роговой гребень* — мөгез тарак, мөгездән эшләнгән тарак; 2. мөгез эшкәртү...-ы; *роговой кустарный промысел* — мөгез эшкәртү эше (кустарь промыселы); 3. быргы...-ы, быргы белән уйнала торган; *роговая музыка* — быргы музыкасы. ◇ **Роговая оболочка** *анат.* — к. роговица. **Роговой камень** *мин.* — к. роговик.

**РОГО'ЖА** *ж.* — чыпта, кап.

**РОГО'ЖИНА** *ж. простореч.* — чыпта кисәге.

**РОГО'ЖКА** *ж.* — 1. чыпта кисәге, чыпта; 2. *спец.* рогожка (җәйге ак кием тегү өчен калын ак тукыма). ◇ **Из кулька в рогожку** — к. кулёк.

**РОГО'ЖНИК** *м.* — чыптачы, чыпта (кап) сугучы.

**РОГО'ЖНЫЙ** — чыпта..., чыптадан эшләнгән; *рогожный куль* — чыпта кап.

**РОГО'З** *м. мн.* нет, *бот.* — җикән, җикәнбаш (су буйларында үсә торган камышсыман кыяклы күпьеллык үлән).

**РОГОЗУ'Б** *м. зоол.* — мөгезтеш (балык).

**РОГОНО'СЕЦ** *м. разг. шутл.* — хатыны хыянәт итә торган ир.

**РОГОХВО'СТ** *м. зоол.*— мөгезкойрык, аерыкойрык (бөҗәк).

**РОГУ'ЛИНА** *ж.*— 1. *обл.* кәкре-бөкре агач, ботаклы-тармаклы агач; 2. *разг. спец.* к. рогуля.

**РОГУ'ЛЬКА** *ж.*— 1. к. рогуля; 2. *обл.* тәкә, бөккән, мөгезсыман күмәч; 3. *тех.* рогулька (эрләү машиналарында җепне бөтерә һәм чорный торган җайланма); 4 *обл.* су чикләвегенең җимеше, батманчык җимеше; 5. *обл. (ошейник)* муендырык, муен агачы (азгын терлеккә тар җирдән үтә алмасын өчен кидерелә торган камытсыман агач җайланма).

**РОГУ'ЛЬНИК** *м.*— 1. *бот.* су чикләвеге, батманчык (үлән); 2. борынчык (бозауга, кәҗә бәрәненә һ. б. анасын иммәсен өчен киертелә).

**РОГУ'ЛЯ** *ж. разг.* и *спец.*— ботаклы-чатаклы әйбер, җәпле (аерылы) әйбер.

**РОД I** *м.*— 1. *этнол.* ыру, ыруг; *старейшина рода* — ыру башлыгы, аксакал; 2. *книжн. (поколение)* нәсел, нәсел-нәсәп, буын, токым; *из рода в род* — нәселдән-нәселгә, буыннан-буынга; *без роду без племени* — нәсел-нәсәпсез; 3. *науч.* ыру (хайваннар һәм үсемлекләр систематикасында). ◇ **Ни роду, ни племени** *устар.*— туганнары (туган-тумачасы) юк, япа-ялгыз, беркеме юк. **На роду написано** — язмышы шул, аның маңгаена язылган. **Род людской** — кешеләр, кешелек. **От роду** — яшь, яшьтә; *ему от роду 20 лет* — ул егерме яшендә, аңа егерме яшь.

**РОД II** *м.*— 1. төр, сорт; *разного рода люди* — һәртөрле кешеләр; 2. рәвеш, төр, юнәлеш; *род жизни* — тормыш (яшәү) рәвеше; *род занятий* — эш төре, нинди эштә эшләү; 3. *лит. устар.* төр, жанр; *драматический род* — драма төре (әдәби жанр). ◇ **В этом (таком) роде** — шуның кебегрәк, шулайрак, шуның шикеллерәк. **В некотором роде** *разг.*— мәгълүм дәрәҗәдә, беркадәр, бераз. **В своём роде** *разг.*— үзенчә, үз урынында, үз алдына; *и весна и осень хороши каждая в своём роде* — яз үз урынында, көз үз урынында яхшы. **Своего рода** *разг.*— үзенә күрә, үзенә бертөрле; *это своего рода уникальная вещь* — бу үзенә күрә уникаль әйбер. **Одного рода** — ырудаш; төрдәш. **Всякого рода, разного рода** — төрле-төрле, һәртөрле, җыен; *всякого рода скотина* — һәртөрле мал-туар; *всякого рода проезжие (прохожие)* — җыен узган-барганнар.

**РОД III** *м. грам.*— род (грамматик категория); *в русском языке имеются существительные мужского, женского и среднего родов* — рус телендә исемнәр мужской, женский һәм средний родта булалар.

**РО'ДИЙ** *м. мн.* нет, *хим.*— родий (көмешсыман ак химик элемент; металл).

**РОДИ'ЛЬНИЦА** *ж. обл.*— яңа гына бала тапкан хатын, бала тудырган хатын, баладан котылган хатын (ана).

**РОДИ'ЛЬНЫЙ** — бала тудыру (бала табу)...-ы; *родильный дом* — бала тудыру йорты. ◇ **Родильная горячка** — тудыру бизгәге (бала тудыручыларда була торган инфекцион авыру).

**РОДИ'МЕНЬКИЙ** *обл.*— к. родимый.

**РОДИ'МЕЦ** *м. обл.*— к. родимчик.

**РОДИ'МЧИК** *м.*— 1. бума чире, зыяндаш (сабый балаларда була торган бума чире); *ребёнок, одержимый родимчиком* — зыяндашлы бала; 2. эклампсия (бала табучыларда була торган тартышу һәм һуш китү авыруы).

**РОДИ'МЫЙ** — 1. *нар.-поэт. разг.* үз, туган, туган-үскән; *родимая сторонушка* — туган-үскән як, үз иле(м); 2. кадерле, газиз; *родимая матушка (батюшка)* — газиз әнкәм (әткәм); *сынок родимый* — кадерле улым; 3. *обл. (ласковое обращение)* туганкай, балакай, бәбкәм, аппагым, акыллым. ◇ **Родимое пятно** — 1. к. родинка; 2. *перен.* (иске тормыш) калдыгы, таплары (эзләре); *родимые пятна капитализма* — капитализм калдыклары.

**РО'ДИНА** *ж.*— 1. туган ил, ватан; *мы любим свой язык и свою родину* — без үзебезнең телебезне һәм ватаныбызны яратабыз; *защищать родину* — (туган) илне саклау; 2. *(место рождения)* туган-үскән җир, туган як, туган авыл (шәһәр); туган йорт; *съездить на родину* — туган авылга (шәһәргә) кайтып килү; 3. *перен.* барлыкка килгән (килеп чыккан, туган) урын; ватан; *родина картофеля — Южная Америка* — бәрәңгенең килеп чыккан урыны — Көньяк Америка.

**РО'ДИНКА** *ж.*— миң.

**РОДИ'НЫ** *ед.* нет, *простореч.*— 1. бишек туе, бәби туе, бәбәй туе (бала тууны бәйрәм итү); 2. *(роды)* бала тудыру; бала табу вакыты, бала туу вакыты.

**РОДИ'ТЕЛИ** *ед.* нет — 1. ата-ана; *его родители живы* — аның ата-анасы исән; 2. *простореч.* борынгы бабалар, ата-бабалар; *не хотим жить, как родители наши жили* — ата-бабаларча гына яшәргә теләмибез.

**РОДИ'ТЕЛЬ** *м. устар.*, теперь *разг. обл.*— ата.

**РОДИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж. устар.*, теперь *разг. обл.*— ана.

**РОДИ'ТЕЛЬНЫЙ: родительный падеж** *грам.*— родительный падеж (татар теленең иялек килешенә якынча туры килә).

**РОДИ'ТЕЛЬСКИЙ** — 1. ата-ана(лар)...-ы; *родительская любовь* — ата-ана мәхәббәте; *родительское собрание* — ата-аналар җыелышы; 2. ата-ана...-ы, туып-үскән; *покинуть родительский дом* — ата-ана йортын ташлап китү, туып-үскән йорттан китү. ◇ **Родительская суббота** *церк. простореч. устар.*— үлгәннәрне искә алу көне.

**РОДИ'ТЬ** *сов.* и *несов.*— 1. *(о женщине)* бала табу, (бала) тудыру, бала китерү, баладан котылу; бәбәйләү; 2. *(о животных)* балалау, бала китерү; 3. *перен.* барлыкка китерү; тудыру, китереп чыгару; *беда беду родит* — бер бәла икенчесен китереп чыгара; 4. уныш (җимеш) бирү; *каменистая земля мало родит* — ташлы җир аз уңыш бирә. ◇ **В чём мать родила** *разг. шутл.*—

анадан тума; яп-ялангач, шәп-шәрә (киемсез).

**РОДИ'ТЬСЯ** *сов.* и *несов.* — 1. туу, дөньяга килү; бала булу; *родился сын* — ир бала туган; *у них родился сын* — аларның уллары бар; 2. *(появиться, возникнуть)* туу, барлыкка килү, килеп чыгу; 3. башка килү, башка төшү, туу; *родилась блестящая идея* — менә диган идея туды, менә диган фикер башка килде; *родилось подозрение* — башка шик төште; 4. уңу; булу; *пшеница родилась хорошо* — бодай яхшы уңды.

**РО'ДИЧ** *м.* — 1. *истор.* ырудаш, бер ырудан; бер ыру члены; 2. *книж. устар. (родственник)* туган, кардәш, агай-эне, туган-тумача, кардәш-ыру; ***наши родичи*** — безнең кардәш-ыру.

**РО'ДНЕНЬКИЙ** *простореч. обл.* — к. родной 3.

**РОДНИ'К** *м.* — 1. чишмә, кизләү; *вода из родника* — чишмә суы; 2. *перен. книж.* чыганак, чишмә; башлангыч; *родник талантов* — талантлар чишмәсе, талантлар чыганагы; 3. *чаще мн.* сөт юлы (хайваннарның җиленәнә сөт килү юлы).

**РОДНИКО'ВЫЙ** — чишмә (кизләү)...-ы; *родниковая вода* — чишмә суы.

**РОДНИ'ТЬ** *несов.* — 1. *редко* туганлаштыру, туганлык (кардәшлек) урнаштыру, туган итү; 2. якынайту, якынлаштыру; якын булу, охшаш булу.

**РОДНИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. туганлашу, туган (кардәш) булу, туганлыкка керү; кодалашу; *не хотел родниться с неприятной ему семьёй* — үзе ошатмаган семья белән кодалашасы (туганлыкка керәсе) килмәде; 2. *(сближаться)* якынлашу, якын мөнәсәбәтләр урнашу; *(приобретать сходство)* охшаш булу, бер-беренә охшау.

**РОДНИЧО'К** I *м. анат.* — лепкә (яшь баланың башында сөяге катып җитмәгән йомшак урын).

**РОДНИЧО'К** II *м.* — к. родник.

**РОДНО'Й** — 1. туган, бертуган, үз; *родной отец* — туган атаң, үз атаң; *родной брат* — бертуган абый, бертуган эне; *родная сестра* — бертуган апа, бертуган сеңел; 2. туып-үскән, туган; *родная страна* — туган ил; *родные края* — туып-үскән яклар; 3. күңелгә якын, үз, газиз; *родное дело* — күңелгә якын эш, үз эшебез; 4. *в знач. сущ.* туганкай, кадерлем, сөеклем; җаным, җанкай, иркәм; *веришь, родная?* — ышанасыңмы, иркәм? ◇ **Родной язык** — ана теле, туган тел. **Родной очаг** — ата йорты, туган-үскән йорт.

**РОДНЫ'Е** *мн. в знач. сущ.* — туганнар, кардәшләр; туган-тумача, агай-эне, кардәш-ыру; *дальние родные* — ерак туганнар; *всюду у него родные* — кая карама, аның кардәш-ыруы.

**РО'ДНЫЙ** *обл.* — к. родной 1, 3.

**РОДНЯ'** *ж. мн.* нет — 1. *собир.* кардәшләр, туганнар; туган-тумача, агай-эне, нәсел-нәсәп; *дальняя родня* — ерак кардәшләр; *близкая родня* — якын кардәшләр; 2. *разг.* кардәш, нәселдәш, туган тиешле кеше; *а тот родня вам* — ә тегесе сезгә туган тиешле кеше.

**РОДОВИ'ТОСТЬ** *ж. мн.* нет — асылзадәлек, затлы нәселдән булу, аксөяклек (борынгы бояр, дворян, морза нәселеннән булу).

**РОДОВИ'ТЫЙ** *устар.* — борынгы аристократик нәселдән..., асылзадә, затлы (нәселдән), аксөяк...; *родовитый дворянин* — затлы дворян.

**РОДОВО'Й** I — 1. нәселдән килгән, нәселдән-нәселгә күчеп килгән, ата-бабадан калган; *родовое имение* — ата-бабадан калган утар; 2. *истор.* ыруглык...-ы; *родовое общество* — ыруглык җәмгыяте; 3. *науч.* ыру...; *родовые и видовые названия растений* — үсемлекләрнең ыру һәм төр атамалары. ◇ **Родовая месть** *истор.* — кан үче, кан үче алу.

**РОДОВО'Й** II *физиол.*: **родовые боли (потуги, схватки)** — тулгак тоту (тудыру авыртулары).

**РОДОВО'Й** III *грам.* — род...-ы; *родовые окончания прилагательных* — сыйфатларның род кушымчалары (рус телендә сыйфатларның кайсы родка караганын белдерүче кушымчалар *-ый, -ая, -ое* кебек).

**РОДОВСПОМОГА'ТЕЛЬНЫЙ** *спец.*: **родовспомогательные учреждения** — бала тудыру йортлары, бала тудыручы хатыннарга ярдәм күрсәтү йортлары.

**РОДОДЕ'НДРОН** *м. бот.* — мурал, Альп розасы (арчанчалар семьялыгыннан матур чәчәкле декоратив үсемлек).

**РОДОНАЧА'ЛЬНИК** *м книж.* — 1. *этногр. истор. (предок)* нәсел башы, ыру башлыгы (баш баба); 2. *перен.* нигезләүче, нигез салучы, башлап җибәрүче; *Горький — родоначальник советской литературы* — Горький — совет әдәбиятына нигез салучы.

**РОДОНАЧА'ЛЬНИЦА** *ж. книж.* — к. родоначальник.

**РО'ДОМ** *нареч.* — чыгышы ягыннан,...-да туган; тумышы белән...-лы; *он родом из Казани* — ул тумышы белән казанлы; *он родом француз* — ул чыгышы (милләте) ягыннан француз.

**РОДОСЛО'ВЕЦ** *м. истор. лит.* — шәҗәрә дәфтәре (нәсел-нәсәп язылган дәфтәр).

**РОДОСЛО'ВИЕ** *ср. книж.* — 1. нәсел, нәсел-нәсәп; 2. шәҗәрә, нәсел агачы, нәсел тарихы, генеалогия (бер нәселдән килгән буыннарның чыгышын һәм кардәшлек дәрәҗәсен билгели торган исемлек).

**РОДОСЛО'ВНАЯ** *ж.* — к. родословие 2.

**РОДОСЛО'ВНЫЙ** *истор.* — нәсел ...-ы; нәсел-нәсәп...-ы; шәҗәрә...-ы; *родословная таблица* — нәсел-нәсәп таблицасы.

**РО'ДСТВЕННИК** *м.*, **РО'ДСТВЕННИЦА** *ж.* — кар(ен)дәш, нәселдәш, туган.

**РО'ДСТВЕННО** *нареч.* — туганнарча, үз итеп, якын күреп; *родственно отнестись к кому-н.* — берәүгә туганнарча якын итеп карау.

**РО'ДСТВЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. туганлык, кардәшлек, якынлык; 2. *(сер-*

*дечность)* туганлыклы булу, туганлык хисе булу, туган җанлы булу; үз күрүчәнлек.

**РО'ДСТВЕННЫЙ** — 1. кардәшлек (туганлык)...-ы; *родственные связи* — кардәшлек бәйләнешләре; *родственные обязанности* — туганлык бурычлары; 2. *перен.* кардәш, тугандаш, семьядаш; (бер)туган; *родственные народы* — кардәш халыклар; *родственные языки* — тугандаш (семьядаш) телләр; 3. *перен.* (бер-берсенә) якын, охшаш, тәрдәш; эргәдәш; *родственные науки* — бер-берсенә якын фәннәр (тәрдәш фәннәр); *родственные идеи* — охшаш фикерләр; 4. туганнардагы, туганнарда була (үткәрелә) торган; *родственные обеды* — туганнардагы мәҗлесләр; 5. туганнарча; якын, самими, кардәше кебек, үз итеп...; *относиться с родственным вниманием* — туганнарча игътибар белән карау, үз итеп карау.

**РОДСТВО'** *ср. мн.* нет — 1. туганлык, кардәшлек; туганлык бәйләнеше, кардәшлек мөнәсәбәте; *ближнее и дальнее родство* — якын һәм ерак туганлык; *кровное родство* — кан кардәшлеге; 2. *собир. разг.* к. родня; 3. *(родственное чувство)* кардәшлек хисе, туганлык тойгысы; 4. *перен.* туганлык, кардәшлек, семьядаш (тугандаш) булу; охшашлык, якынлык; *родство языков* — тел кардәшлеге, телләрнең охшашлыгы; *родство идей* — фикерләрнең якынлыгы. ◇ **Не помнящий родства** *дореволь. офиц.* — нәсел-нәсәбен оныткан (элекке заманда үзенең чыгышы, тумышы, ата-анасының кемлеге турында власть нязләренә мәгълүмат бирмәүче кеше); *Иван, не помнящий родства* — нәсел-нәсәбен оныткан кеше.

**РО'ДЫ** *ед.* нет — тудыру, бала табу, бала тудыру, бала китерү; бәбәйләү; *первые роды* — беренче тапкыр тудыру, беренче бала табу. ◇ **Способствовать родам** — акушерлык (әбилек) итү, тудыруга ярдәм күрсәтү.

**РОЁВКА** *жс. обл.* — к. роевня.

**РОЕ'ВНИК** и **РОЁВНИК** *м. обл. спец.* — к. роевня.

**РОЕ'ВНЯ** и **РОЁВНЯ** *жс. спец.* — корт тубалы (бал кортлары күчен җыеп ала торган тубал).

**РОЕВО'Й** *спец.* — күч...-ы; *роевые пчёлы* — күч кортлары (умартадан аерылып чыккан кортлар).

**РОЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — к. роиться.

**РО'ЖА** I *жс.* — 1. *простореч.* йөз, бит, авыз-борын, төс-бит; *пьяная рожа* — исерек йөз; *нечего на зеркало пенять, коли рожа крива* — авызың чалыш булгач, көзгегә үпкәләмә; 2. *разг. фам. (уродливое лицо)* килешсез бит, килбәтсез йөз; 3. *простореч. фам.* гарип йөзле, бик ямьсез кеше; 4. *простореч. устар.* битлек, маска. ◇ **Корчить (строить, делать) рожу** — к. гримасничать. **Ни кожи, ни рожи** — аның ни буе да, ни төсе (бик ямьсез кеше турында әйтелә).

**РО'ЖА** II *жс. мн.* нет, *мед.* — рожа (йогышлы тире авыруы).

**РОЖА'ТЬ** *несов. простореч.* — к. родить 1, 4.

**РОЖДА'ЕМОСТЬ** *жс. мн.* нет, *офиц.* — бала туу, туу саны, туым.

**РОЖДА'ТЬ** *несов.* — к. родить.

**РОЖДА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. родиться; 2. *страд.* (бала) тудырылу, (бала) табылу.

**РОЖДЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед. книжс.* — к. рождать, рождаться; 2. туган вакыт, туган көн; туган көн бәйрәме; *приду к тебе на рождение* — синең туган көнеңә килермен, туган көн бәйрәмеңә килермен. ◇ **От рождения** — тумыштан, тума; *глухой от рождения* — тумыштан саңгырау; *слепой от рождения* — тума сукыр. **1920 года рождения** — 1920 елгы, 1920 елда туган.

**РОЖДЕ'ННИК** *м.*, **РОЖДЕ'ННИЦА** *жс. простореч.* — туган көнен бәйрәм итүче, туган көнен үткәрүче.

**РОЖДЁННЫЙ** — 1. ту(дырыл)ган, дөньяга килгән, барлыкка килгән; иҗат ителгән; 2. ...-ырга туган, ...өчен яралган; *рождённый ползать — летать не может (М. Горький)* — шуышырга яралган — күкләрдә оча алмас.

**РОЖДЕ'СТВЕНСКИЙ** *устар.* — рождество...-ы; раштуа...-ы; рождествода була торган; *рождественские морозы* — раштуа суыклары (кышкы салкыннар).

**РОЖДЕСТВО'** *ср. мн.* нет, *церк.* — 1. рождество, раштуа (христиан динендә — 25 нче декабрьда үткәрелә торган дини бәйрәм); 2. *старин.* к. рождение.

**РОЖЕ'НИЦА** *жс.* — бала табучы хатын (тудырыр вакыты якынлашкан йөкле хатын).

**РОЖЕ'СТВЕНСКИЙ** *разг.* — к. рождественский.

**РОЖЕ'ЧНИК** *м.* — быргычы, быргыда уйнаучы, быргы кычкыртучы.

**РО'ЖКИ** *мн.* — к. рожок I.

**РОЖКИ'** *только мн.* — 1. *обл. с.-х. (спорынья)* арыш анасы; 2. вак макарон (макаронның бер төре). ◇ **Цареградские рожки** *(стручки)* — баллы (татлы) кузак, кәҗә мөгезе (кузаклы җимеш).

**РОЖНЕ'Ц** *м. обл.* — ыргак (эскерттән салам яки печән йолку өчен тимер яки агач ыргак).

**РОЖО'К** I *м. (мн. рóжки)* — кечкенә мөгез, мөгезчек; *рóжки улитки* — әкәм-төкәмнең мөгезчекләре (мөгезсыман үсентеләре).

**РОЖО'К** II *м. (мн. рожки́)* — 1. быргы; *пастуший рожок* — көтүче быргысы; 2. *(табакерка)* тәмәке савыты (мөгездән ясалган); 3. колак трубкасы (саңгыраулар өчен); 4. имезгеч, имезлекле шешә (яшь балаларга сөт эчерү өчен имезлек кидерелгән шешә); 5. рожок; җәп, тармак; *газовый рожок* — газ рожогы (газ трубасы, көпшәсе); *рожки канделябра* — кандил җәпләре; 6. *(лопаточка для обуви)* рожок, калакча (башлыча, галош кигәндә кулланыла).

**РОЖО'Н** *м. обл. устар.* — очлы казык, сөңге (авыш хәлдә беркетелгән очлы казык). ◇ **Лезть (идти) на рожон** *разг.* —

үз-үзеңне бәлагә тыгу, күрәләтә утка керү. **Какого рожна** (надо, не достаёт)? *просто-реч. вульг.*— нәрсә кирәк тагы? ни пычагым кирәк (житми)? **На какой рожон** *простореч.*— ни пычагыма? ни өчен? нигә? **Ни рожна** *простореч.*— берни, берни дә. **Против рожна** (идти, переть) *простореч.*— юкка көчәнү.

**РОЖЬ** *ж.*— 1. арыш; 2. *только мн.* арышлар, арыш басуы; *нынче ржи хороши* — быел арышлар яхшы.

**РО'ЗА** *ж.*— 1. роза, гөлчәчәк (үсемлек һәм аның чәчәге); 2. (гөлчәчәк рәвешендәге) бизәк, нәкышь; 3. *архит.* (готик стильдә гөлчәчәк рәвешендә эшләнгән) түгәрәк тәрәзә. ◇ **Роза ветров** *геогр.*— җилләр розасы (күп чатлы йолдыз рәвешендә төзелгән диаграмма; аның һәр чаты — җилнең юнәлешен, ә чатның озынлыгы җилнең дәвамлылыгын һәм кабатланышын күрсәтә). **Дикая роза** *бот.*— гөлҗимеш, гөләп, аю камыры. **Роза золотая** *бот.*— алтын камчы (үсемлек).

**РО'ЗАН** *м.*— 1. *разг.* к. роза 1; 2. розан (булка төре); 3. *перен. разг. фам.* сөйкемле, ягымлы, гүзәл (балалар, хатын-кызлар турында әйтелә).

**РОЗАНИЛИ'Н** *м. хим. тех.*— розанилин (тукыма һәм кәгазьләрне кызыл төскә буяу матдәсе).

**РОЗАНИЛИ'НОВЫЙ** *хим. тех.*— розанилин(нан ясалган)...; *розанилиновые краси-тели* — розанилин буяулар.

**РОЗА'РИИ** *м.*— роза бакчасы (питомнигы); гөлчәчәк бакчасы.

**РО'ЗБИТЬ** *ж. мн.* нет, *собир. спец.*— аерым нөсхәләр, таркау өлешләр (мәсәлән, күп томнардан торган китапның аерым-аерым нөсхәләре); 2. *устар.* вак герләр.

**РО'ЗВАЛЬ** *ж. мн.* нет, *собир. просто-реч.*— тәртипсез өем, ташландык, ыбыр-чыбыр (ничек туры килсә шулай ташланган төрле әйберләр өеме).

**РО'ЗВАЛЬНИ** *ед.* нет — үрәчәле чана, терәкле чана (печән чанасы).

**РО'ЗВЯЗЬ** *ж. обл.*— 1. *только ед. собир.* чәчелеп яткан, бәйләнмәгән нәрсә (мәсәлән, көлтәгә бәйләнмәгән урылган иген); 2. *только ед., перен. спец., охот.* житезлек, елгырлык, хәрәкәтчәнлек (ау эте турында әйтелә).

**РО'ЗГА** *ж.*— 1. чыбык, тал чыбыгы, сыек (пеше) чыбык; 2. *только мн. устар.* суктыру, чыбыклау; суктыру җәзасы; *дать розог* — чыбык белән суктыру.

**РО'ЗГОВЕНЬЕ** *ср. мн.* нет, *церк. устар. простореч.*— 1. *(действие)* к. разговляться; 2. *(первый день мясоеда)* авыз ачкан көн (христиан динендә ураза бетеп, ит ашый башлаган көн).

**РО'ЗГОВИНЫ** *ед.* нет, *разг. устар.*— к. разговенье.

**РО'ЗДЫХ** *м. мн.* нет, *простореч.*— аз гына (эш арасында) ял итеп алу, бераз тын алу.

**РОЗЕИ'Н** *м. мн.* нет — розеин (буяу матдәсе).

**РОЗЕО'ЛА** *ж. мед.*— кызыл тап, кызыл тимгел (йогышлы авыруларның галәмәте булган кечкенә таплар).

**РОЗЕ'ТКА** *ж.*— 1. розетка (хатын-кыз күлмәге, эшләпәсе һәм туфлиләрендә чәчәк яки яфраксыман бизәк); 2. кечкенә тәлинкә, варенье тәлинкәсе; 3. шәм калпагы (эрегән шәм шәмдәлгә таммасын өчен шәмгә киертелә); 4. *тех.* розетка (электр выключателе астында стенага беркетеп куела торган түгәрәк агач яки фарфор); 5. *устар.* орден банты, орден лентасы; 6. *архит. (лепное украшение)* яфрак-чәчәксыман бизәк, нәкышь.

**РОЗЕ'ТТА** *ж. архит.*— к. розетка 6.

**РО'ЗЛИВ** *м. простореч.*— к. разлив 2.

**РО'ЗЛИВЕНЬ** *м. обл.*— ташу, ташкын, су ташуы.

**РОЗМАРИ'Н** *м.*— 1. *бот.* бәбрия, розмарин (чәчәгеннән хуш исле май алына торган куак үсемлек); 2. *сад.* розмарин сортлы алма.

**РОЗМАРИ'НОВЫЙ, РОЗМАРИ'ННЫЙ** — розмарин...-ы; бәбрия...-ы; *розмариновое масло* — розмарин мае, бәбрия мае.

**РО'ЗМАХ** *м. мн.* нет, *обл.* — к. размах.

**РО'ЗНИТЬ** *несов. простореч.*— 1. аеру; *судьба рознит нас* — язмыш безне аера; 2. комплектын бозу, ишеннән (сыңарыннан) аеру; 3. *обл. (иметь отличие)* аерылып тору, охшамау, аермалы булу.

**РО'ЗНИТЬСЯ** *несов. разг.*— аерылу, аерылып тору, аермалы булу, охшашлык булмау, охшамау.

**РО'ЗНИЦА** *ж. мн.* нет, *торг.*— 1. ваклап сату; 2. ваклап сатыла торган товар. ◇ **Продавать оптом и в розницу** — к. оптом.

**РО'ЗНИЧНЫЙ** *торг.*: **розничная торговля** — ваклап сәүдә итү; **розничная продажа** — ваклап сату; **розничные товары** — ваклап сатыла торган товарлар.

**РО'ЗНО** *нареч. разг.*— аерым-аерым, аерылып, үз башына; *жить розно* — аерым-аерым яшәү.

**РО'ЗНЫЙ** *обл.*— 1. *(раздельный)* аерым; 2. *(непарный)* ишсез, сыңар, парсыз; 3. *(дырявый)* ертык, тишек.

**РОЗНЬ** *ж. мн.* нет, *разг.*— 1. *(вражда, несогласие)* дошманлык, дау, ара бозылу, килешә алмау; бәхәс, талаш; 2. *в знач. сказ.* аерылып тора, охшамый, аермалы, үзенә башка.

**РОЗОВА'ТЫИ** — алсу, алсу төсмерле.

**РОЗОВЕ'ТЬ** *несов.*— алсулану, аллану; кызару, алсу-кызыл төскә керү; *лицо розовеет от мороза* — суыктан йөзе (бите) алсулана.

**РОЗОВИ'К** *м. мин.*— алсу кварц, алсу шпат.

**РО'ЗОВЫЕ** *мн. в знач. сущ. бот.*—розачалар, гөлчәчәкләләр семьялыгы.

**РО'ЗОВЫЙ** — 1. роза...-ы; гөлчәчәк...-ы; *розовый куст* — роза (гөлчәчәк) куагы; 2. ал, алсу, алсу-кызыл; 3. *перен. ирон.* алды-гөлле, ал да гөл; татлы, тәмле; (һәммә нәрсә) яхшы, матур, саф; *розовые мечты* —

татлы хыяллар; *розовая любовь* — саф мәхәббәт (гөнаһсыз, самими мәхәббәт). ◇ **Видеть всё в розовым свете** — идеаллаштыру, барысын да ал да гөл итеп күрү. **Смотреть на всё сквозь розовые очки** — һәрнәрсәгә алсу күзлек аша карау (кимчелекләргә күз йомып үтү). **Розовый осот** *бот.* — каты билчән.

**РО'ЗОЧКА** *ж.* — 1. к. роза; 2. *ювелир.* брильянт бөртеге; кечкенә брильянт.

**РОЗОЦВЕ'ТНЫЕ** *мн. бот.* — к. розовые.

**РО'ЗЫГРЫШ** *м.* — 1. разыграть; 2. отыш уены, уйнау, уйналу, тираж, (беренчелекне билгеләү өчен булган) ярыш, уен; *розыгрыш займа* — заём уйналу, заём тиражы; *розыгрыш первенства СССР по футболу* — футбол буенча СССР беренчелегенә ярышлар үткәрү; 3. *спорт.* бер якның да отмавы белән беткән уен.

**РО'ЗЫГРЫШНЫЙ: розыгрышная игра** — бер якның да отмавы белән беткән (тагын уйналырга тиеш булган) уен; **розыгрышная таблица** — отышлар таблицасы, тираж таблицасы.

**РО'ЗЫСК** *м.* — 1. к. разыскать 1; 2. суд тикшерүе, җинаятьчене эзләү, җинаятьне тикшерү; башлангыч тикшерү, сорау (җавап) алу; дәлилләр җыю (хөкем итү өчен суд алдыннан); *производство розыска* — җинаятьне тикшерү; *пытка в старину была главным средством розыска* — элек суд тикшерүләренең төп чарасы җәзалау булган (сорау алганда җәза кулланылган); 3. *устар.* (*исследование*) өйрәнү, тикшеренү, эзләнү, гыйльми хезмәт, язма. ◇ **Уголовный розыск** *офиц.* — (милициянең) җинаятьләр тикшерү бүлеге.

**РОЗЫСКНО'Й** — к. разыскной.

**РОИ'СТЫЙ** *с.-х.* — күп күч аера торган; *роистый улей* — күп күч аера торган умарта.

**РОИ'ТЬ** *несов. с.-х.* — бер кучкә кушу, бер илгә берләштерү; бер оягә туплау, җыйнау (умарта кортларын).

**РОИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *с.-х.* (*о пчёлах и т. п.*) умарта аеру, корт аеру, күч аеру, күч очыру, күч чыгару; ил (семья, оя) аеру; 2. (*летать роем*) мыжж (гөжж) килеп очу, каплап (сарып) алу, күч кебек очу, өер булып (төркем-төркем) очып йөрү; 3. *перен.* (башта фикерләр, уйлар) кайнау, кайнашу; бер-бер артлы агылу, агып тору.

**РОЙ** *м.* — 1. күч, умарта иле, умарта күче, бер оя корт (бал кортлары); 2. чебенчерки көтүе, өер, төркем; көтү, күч; *над головой вьётся рой мух* — баш очында бер көтү чебен оча; 3. *перен.* (*множество*) көтү-көтү, төркем-төркем, өер-өер.

**РОЙБА'** *ж. мн.* нет, *с.-х. обл.* — 1. к. роение; 2. (*период роения*) корт аерган вакыт, умарталар аерган чак.

**РОЙНИ'К** *м.*, **РОЙНИ'ЦА** *ж. с.-х.* — корт тубалы, күч тубалы.

**РО'ЙНЫЙ** — 1. к. роистый; 2. күч...-ы; ил...-ы; *ройная матка* — күч анасы, аерылып чыккан умарта күченең анасы.

**РОК** *м. мн.* нет, *книж.* — 1. *поэт. устар.* (*судьба*) язмыш, тәкъдир; *по воле рока* — язмыш ихтыяры белән, тәкъдирдә яз(ыл)ган буенча; 2. *миф.* кодрәт, гайре табигый куәт; алла (ходай) ихтыяры.

**РОКА'ДА** *ж. спец.* — рокада (фронт сызыгына параллель барган юл).

**РОКА'ЙЛЬ** *ж. нескл. архит.* — рокайль (элекке рококо стилендә кулланылган, кабырчык һәм кыя ватыклары рәвешендәге орнамент).

**РОКИРОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. шахм.* — к. рокироваться.

**РОКИРОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов. шахм.* — рокировка ясау.

**РОКИРО'ВКА** *ж. шахм.* — рокировка (шахмат уенында мәгълүм шартларда, ладьяны король янына китереп, корольне аның икенче ягына сикертеп кую); *длинная рокировка* — озын рокировка (сул якта).

**РОКОВО'Й** *книж.* — 1. *устар. поэт.* бәхетсез, кайгы (бәла-каза) китерә торган; шомлы, шомланулы; тәкъдир язган; *роковая любовь* — бәхетсез (шомлы) мәхәббәт; 2. хәлиткеч, язмышы хәл итеlә торган; *роковая минута* — хәлиткеч минут; 3. һәлакәтле, хәтәр, хәвефле, куркынычлы, һәлакәткә алып бара торган; төзәтә алмаслык; *роковая ошибка* — төзәтә алмаслык хата; *роковая болезнь* — хәтәр авыру (ахыры үлем белән бетүе мөмкин булган авыру).

**РОКК** *м.* (Российское общество Красного Креста) — РОКК (Россия Кызыл Хач җәмгыяте).

**РОКОКО'** *ср. нескл. архит. искус.* — рококо (архитектурада һәм бизәү сәнгатендә 18 гасыр башларында барлыкка килгән бик катлаулы, купшы стиль).

**РО'КОТ** *м. мн.* нет, *книж.* — гөрелте, гөрләү; гүләү, шау-гөр, шау-шу; шаулау, гөрелдәү, гөрелдәвек; күкрәү, күкрәп ишетелү; гөр(с)елдәгән тавыш; *рокот моря* — диңгез шаулавы; *рокот канонады* — туплар гөрселдәве. ◇ **Рокот соловьиный** — сандугач сайравы (чутылдавы).

**РОКОТА'НИЕ** *ср. книж. поэт.* — к. рокотать.

**РОКОТА'ТЬ** *несов. книж. поэт.* — гөр(с)елдәү; гөрләү, гүләү, күкрәү, шаулау, гөр килү, гү килү, шау-гөр килү, гөрләп тору; шау-шу килү, чыр-чу килү.

**РОКФО'Р** *м. мн.* нет — рокфор (сарык сөтеннән ясалган сыр).

**РОЛ** *м. спец.* — 1. вал, каток; 2 рулон (цилиндр рәвешендә уралган кәгазь яки башка нәрсә); *рол бумаги* — кәгазь рулоны.

**РОЛЕВО'Й, РО'ЛЕВЫЙ** *спец.* — к. рольный 1, 2.

**РО'ЛИК** *м.* — 1. кечкенә рулон; *ролик бумаги* — бер кечкенә рулон кәгазь; 2. кечкенә тәгәрмәч, ролик, катушка; *рояль на роликах* — роликлы рояль (күчереп йөртү өчен кечкенә тәгәрмәчләре булган рояль); 3. (*блок*) кечкенә чыгыр, блок; 4. *тех.* фарфор изолятор, ролик (электр, телеграф чыбыкларын беркетү өчен чынаяк кәтүк); 5. *только мн. спорт.* тәгәрмәчле тимераяк, роликлы тимераяк; *кататься на роликах* — роликлы тимераякта шуу; 6. *тех.* ролик

(машинаның кечкенә цилиндр яки вал формасындагы кисәге).

**РО'ЛИКОВЫЙ** *тех.*— роликлы, чыгырлы, тәгәрмәчле; *роликовое сиденье* — роликлы утыргыч. ◇ **Роликовый конвейер (транспортёр)**— к. рольганг.

**РО'ЛЛЕР** *м.*— роллер (бер аяк белән басып, икенчесе белән этеп йөртелә торган уенчык самокат).

**РОЛЬ** *ж.*— 1. *театр.* роль; *главная роль* — төп роль; *трудная роль* — авыр роль; *списывать роль* — рольне язып алу (башкаласы рольгә караган сүзләрне, репликаһәм монологларны күчереп алу); 2. *перен.* роль, (берәүнең берәр эшкә) катнашу дәрәҗәсе, керткән өлеш, хезмәт, тоткан урын, әһәмият; *ему принадлежит большая роль в этом деле* — аның бу эштә роле зур. ◇ **В роли (быть)** *перен.*— ...сыйфатында, рәвешендә; ...булып, буларак; *выступить в роли обвинителя* — гаепләүче сыйфатында чыгыш ясау. **Войти в роль** *кого-н. перен.*— ...роленә керү (ягъни берәүнең эшен, кыланышын, үзен тотышын, йөреш-торышын үзләштерү). **Выдержать свою роль** *перен.*— үз ролен ахырынача башкарып чыгу (үз өстенә алган вазифаны яки кыланышны ялгышмыйча бик оста үтәп чыгу). **Знать свою роль** *перен.*— үз эшен белү, белеп эш итү, ышанычлы хәрәкәт итү. **Играть роль** *перен.*— зур роль уйнау, йогынтысы (тәэсире) зур булу; *он играет там роль* — ул анда зур роль уйный, аның анда йогынтысы зур (сүзе үтә). **Играть роль** *кого-чего* **или** *какую* — 1. роль уйнау, әһәмиятле булу; *качество материала играет большую роль* — материалның сыйфаты зур роль уйный (сыйфаты бик әһәмиятле); 2. ...ролен үтәү, хезмәтен үтәү; *углекислый аммоний в печении хлеба играет роль дрожжей* — углекислый аммоний икмәк пешерүдә чүпрә хезмәтен үти; 3. булып кыланy; *ему как-то нравилось играть роль страдальца* — ул нигәдер җәфа чигүче булып кыланырга бик ярата иде.

**РОЛЬГА'НГ** *м. тех.*— рольганг, роликлы конвейер (йөкләрнең үз авырлыгы тәэсире белән хәрәкәт итә торган конвейер).

**РО'ЛЬНЫЙ** *тех.*— рулон(лы), катушкалы, рулонга (катушкага) уралган; *рольная бумага* — рулонга уралган кәгазь.

**РО'ЛЯ** I *ж. устар.*— к. роль.

**РО'ЛЯ** II *ж. обл.* и *старин.*— сөрелгән кыр, чәчү кыры, чәчү җире, басу.

**РОМ** *м. мн.* нет — ром (шикәрдән ачытылган көчле спиртлы эчемлек).

**РОМА'Н** I *м. лит.*— роман (гадәттә проза белән язылa торган катлаулы сюжетлы зур әдәби әсәр).

**РОМА'Н** II *м. разг.*— (ике кеше арасында) роман, мәхәббәт, гыйшык, сөешү.

**РОМАНЕ'СКА** *ж. истор.*— романеска (итальян биюе).

**РОМАНЕ'Я** *ж. мн.* нет, *истор.*— романея (Пётр I гә кадәрге Русьта чит илләрдән китерелгән югары сортлы виноград аракысы).

**РОМАНИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *истор.*— романлаш(тыр)у, романизация (борынгы заманда — Көнбатыш Европа халыкларының роман культурасын һәм телен үзләштерүләре).

**РОМАНИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. истор.*— романлаштыру, Рим культурасын кертү.

**РОМАНИЗИ'РОВАТЬСЯ** *истор.*— 1. *сов.* и *несов.* романлашу, Рим культурасын (латин телен) үзләштерү; 2. *несов. страд.* романлаштырылу.

**РОМАНИ'ЗМ** *м. лит.*— романизм (роман телләреннән кергән сүзләр һәм әйләнмәләр; роман телләренә нярүдән туган тел үзенчәлекләре).

**РОМАНИЗОВА'ТЬ(СЯ)** *сов.* и *несов. истор.*— к. романизировать(ся).

**РОМАНИ'СТ** I *м.*— романист, роман язучы.

**РОМАНИ'СТ** II *м.*— романист (1. роман телләре һәм әдәбияты галиме; 2. *юр.* Рим хокукы белгече).

**РОМАНИ'СТИКА** *ж. мн.* нет — романистика (роман халыклары культурасын, телен һәм әдәбиятын өйрәнә торган фән; роман филологиясе).

**РОМАНИСТИ'ЧЕСКИЙ** *книж.*— романистик, романистикадагы, романистика өлкәсендәге.

**РОМАНИ'СТКА** *ж.*— к. романист I, II.

**РОМАНИ'СТСКИЙ** — романист...-ы, романистларча..., роман язучыларча...; *романистский подход* — романистларча караш.

**РОМАНИ'ЧЕСКИ** *нареч.*— роман(дагы)ча, романга хас булганча, романга хас рәвештә; *события развиваются весьма романически* — вакыйгалар нәкъ романдагыча җәелеп баралар.

**РОМАНИ'ЧЕСКИЙ** I — романга охшаган, романга хас булган.

**РОМАНИ'ЧЕСКИЙ** II — мәхәббәт (гыйшык)...-ы; *романические приключения* — мәхәббәт маҗаралары.

**РОМА'ННЫЙ** *лит.*— роман кебек, романдай, романча...; *романное построение литературного произведения* — әдәби әсәрнең романча төзелеше.

**РОМА'НС** *м.*— романс (1. *муз.* лирик эчтәлекле кечкенә музыкаль әсәр; 2. *лит.* мәхәббәт темасына язылган кечкенә генә лирик шигырь).

**РОМА'НСКИЙ** *науч.*— роман...-ы; *романская культура* — роман культурасы; *романские языки* — роман телләре (латин халык теле нигезендә барлыкка килгән француз, провансаль, итальян, испан, португаль, каталон, румын, рето-роман телләре). ◇ **Романская филология** — к. романистика.

**РОМА'НСНЫЙ** — романс...-ы; *романсный стиль* — романс стиле.

**РОМАНТИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.*— романтиклаштыру, идеаллаштыру, романтик буяулар белән сурәтләү; *романтизировать чью-н. личность* — берәр шәхесне идеаллаштыру.

**РОМАНТИЗИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.*

*книж.*— романтиклаштырылу, идеаллаштырып җибәрелү, романтик төстә сурәтләнү, артык макталу.

**РОМАНТИ'ЗМ** *м. мн.* нет — романтизм (1. XIX йөзнең башында әдәбиятта һәм сәнгатьтә барлыкка килгән, чынбарлыктан читкә китеп, үткәнне идеаллаштырып күрсәтү, хыял-тойгы дөньясына бирелү һәм шәхес культы белән характерлана торган юнәлеш; 2. әдәбият һәм сәнгатьтә оптимизм белән сугарылган һәм кешенең бөеклеген ачык образларда күрсәтергә омтыла торган юнәлеш; *революционный романтизм М. Горького*— М. Горькийның революцион романтизмы; 3. *книж.* романтиклык, чынбарлыкны идеаллаштыру, хыялга (тойгыга, хискә) бирелү.

**РОМА'НТИК** *м.* — 1. романтик, романтизм тарафдары; *борьба романтиков с классицистами* — романтизм тарафдарларының классицизм тарафдарлары белән көрәше; 2. *перен.* романтик, романтикага бирелгән кеше; хыялга бирелүчән кеше.

**РОМА'НТИКА** *ж. мн.* нет, *книж.*— 1. к. романтизм 3; 2. романтика; *романтика борьбы за свободу* — азатлык өчен көрәш романтикасы; 3. романтик әдәбият (сәнгать), романтик әсәрләр; *читать романтику* — романтик әсәрләр уку; *увлекаться романтикой* — романтик әдәбият белән мавыгу.

**РОМАНТИ'ЧЕСКИЙ** *книж.*— 1. романтизм...-ы; романтик, романтизм рухындагы; *романтическая школа* — романтизм мәктәбе; *романтическая поэзия* — романтик поэзия; 2. *(мечтательный)* хыялланучан, романтикага (хыялга) бирелүчән, хис-тойгыга бирелүчән, нечкә күңелле; романтик хисле; 3. к. романический II; *романтические похождения* — романтик мажаралар (мәхәббәт мажаралары).

**РОМАНТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— романтиклык, хыялга бирелүчәнлек.

**РОМАНТИ'ЧНЫЙ** *книж.*— к. романтический 2.

**РОМА'ШКА** *ж.*— 1. *бот.* ромашка, акчәчәк; ромашка чәчәге; 2. *мед.* ромашка суы (дару); 3. *разг.* ромашка порошогы (кандала, борча кебекләргә каршы кулланыла).

**РОМА'ШКОВЫЙ** *спец.*— ромашка ..-ы; акчәчәк...-ы; *ромашковое масло* — ромашка мае; *ромашковый настой* — акчәчәк төнәтмәсе.

**РОМБ** *м.*— ромб (1. *мат.* кырлары үзара тигез булган параллелограмм; 2. *разг.* тигезкырлы кыек дүртпочмак; кыек шакмак, ягъни турыпочмаклы түгел; 3. *воен. устар.* кыек дүртпочмак рәвешендәге хәрби дәрәҗә билгесе).

**РОМБИ'ЧЕСКИЙ** *книж.*— ромбик, ромб формасындагы, ромб рәвешендәге, кыек дүрткел рәвешендәге.

**РОМБОВИ'ДНЫЙ** *науч.*— ромбка охшаган, ромбсыман, ромб шикелле, кыек дүртпочмаксыман.

**РО'МБОВЫЙ** *разг.*— к. ромбический.

**РОМБО'ИД** *м. мат.*— ромбоид, параллелограмм.

**РОМБОИДА'ЛЬНЫЙ** *мат. мин.*— ромбоидаль, ромбоид формасындагы; (ян яклары) ромбоидлардан торган.

**РОМБО'ИДНЫЙ** *мат.*— ромбоидсыман.

**РОМБО'ЭДР** *м.*— ромбоэдр (һәр ягы ромбтан гыйбарәт булган параллелепипед).

**РОМБОЭДРИ'ЧЕСКИЙ** *мат. мин.*— ромбоэдрик, ромбоэдр формалы, ромбоэдрсыман.

**РО'МОВЫЙ** — 1. ром...-ы; *ромовый запах* — ром исе; 2. ромлы, ром белән (ром салып) хәзерләнгән; *ромовая баба (кулин.)*— ромлы пирожный (ром сеңдерелгән татлы күмәч).

**РО'НДИК** *м. спец.*— рондик (ат йөгәненең өске өлеше).

**РО'НДО** *ср. нескл. муз.*— рондо (төп темасы берничә тапкыр кабатлана торган музыкаль әсәр).

**РОНДО'**[1] *ср. нескл.* — 1. *лит.* рондо́ (аерым юллары билгеле бер тәртиптә кабатлана торган шигырь төре); *простое рондо* — гади рондо (13 юллы); *сложное рондо* — катлаулы рондо (24 юллы); 2. рондо шрифты (басма һәм язма); 3. рондо каләм (калын язу өчен кулланыла торган яссы очлы каләм).

**РО'НЖА** *ж.*— 1. *зоол.* урман каргасы; 2. *спец.* сал беркетә торган аркылы борыс.

**РОНИ'ТЬ** *несов. обл.*— 1. кисү, чабу; кисеп аудару, кисеп егу; кисеп (чабып) ташлау; *ронить лес* — урман кисү; *ронить траву* — үлән чабу; 2. *перен.* әйтү, сүз кату, сүз кушу; *что не ронишь слова ласкового?*— нигә бер ягымлы сүз дә әйтмисең?

**РОНЯ'ТЬ** *несов.*— 1. *(выпускать из рук)* кулдан төшерү, төшереп җибәрү, коюу; чәчү; 2. *(потерять)* төшереп югалту, төшереп калдыру, коеп бетерү; 3. *(опрокидывать, сбивать)* төртеп аудару, егу; аударып түгү, чәчү; 4. салу, асылындыру, салындыру; *ронять голову на грудь* — башын күкрәгенә салындыру (хәлсезлектән); 5. коюу; йон (ябага) коюу; *деревья роняют листву* — агачлар яфрак коя; *ронять волосяной покров* — ябага коюу; 6. *перен. ритор.* түгү, агызу; тамызу, тамып тору, саркып (агып) тору; *ронять слёзы* — күз яшьләре түгү; *ронять капли крови* — кан тамып тору, саркып тору; 7. *перен.* әкрен генә әйтү, ялкау гына сүз кату, сүз кушкалау; *ронять слова* — ялкау гына, сүз кушу; 8. *перен.* (авторитетын) төшерү, (абруен) китәрү; *ронять своё достоинство* — авторитетыны төшерү.

**РОПА'К** *м. спец.*— ропак, текә боз кисәге (төньякта тигез боз өстендә чыгып торган боз кисәге).

**РОПАТА', РО'ПАТЬ** *ж. истор.*— гыйбадәтханә (православный булмаган диннәрнең гыйбадәт йортларының борынгы исеме: мәчет, кирка һ. б. ш. кебекләр).

**РО'ПОТ** *м. мн.* нет — 1. сукрану, зарлану, зар; ризасызлык (белдерү), ризасызлык авазы, мыгырдану; рәнҗү; *по толпе пробежал ропот* — халык ризасызлык белде-

реп шаулап алды; 2. *перен. поэт.* шаулау; кыштырдау, гөрелте, чылтырау; *ропот волн* — дулкыннар шаулавы.

**РОПОТЛИ'ВЫЙ** — сукранучан, зарланучан, шыңшырга (мыгырданырга) яратучан, мыгырдык; *ропотливый старик* — сукранучан карт.

**РО'ПОТНЫЙ** — 1. *(невнятный)* мыгыр-мыгыр (быдыр-быдыр) килеп..., мыгырдап...; аныксыз, аңлашылмый торган, ачык булмаган; *ропотная речь* — мыгырдап сөйләү; 2. шаулы; шаулап торган, гүелдәп (чылтырап) торган; *ропотная волна* — шаулы дулкыннар.

**РОПТА'НИЕ** *ср. мн.* нет — к. роптать.

**РОПТА'ТЬ** *несов.* — сукрану, зарлану, рәнҗү, ризасызлык белдерү, җәберсенү.

**РОСА'** *ж.* — чык. ◇ **Медвяная или медовая роса** *бот.* — баллы чык (үсемлекләрдә гөмбә авыруы). **По росе** — 1) чыклы вакытта, чык кипкәнче; *хорошо косить (траву) по росе* — үләнне чыклы вакытта чабарга яхшы; 2) чыклы җирдә, чыклы үләндә. **До росы** — бик иртә, иртә таңнан. **Роса мучнистая** — ончыл чык (үсемлекләр авыруы).

**РОСИНА'НТ** *м. книж. ирон.* — чиктән тыш арык ат, росинант (Сервантесның „Дон-Кихот" романындагы Дон-Кихот атының кушаматыннан алынган).

**РОСИ'НКА** *ж.* — 1. чык тамчысы; 2. *обл.* бер бөртек. ◇ **Маковой росинки во рту не было** *разг.* — бер валчык та капканым юк.

**РОСИ'СТЫЙ** — 1. чыклы; чыкланган; чык төшкән, юеш; *росистая тропинка* — чыклы сукмак; 2. чык төшә торган; *росистые ночи* — чык төшә торган төннәр.

**РОСИ'ТЬ** *несов.* — 1. *безл.* чыклану, чык төшү; *ночью сильно росило* — төнлә бик нык чык төште; 2. *(о дожде)* вак яңгыр сибәләү, сибәләп тору.

**РОСИ'ЧКА** *ж. бот.* — кыргый тары, кыр тарысы.

**РОСКО'ШЕСТВО** *ср.* — 1. к. роскошь; 2. бай тормыш, иркен тормыш, мул-рәхәт тормыш; *дни роскошества* — мул-рәхәт тормыш кичергән чаклар; 3. *только ед.* артык зиннәткә омтылу, артык зиннәт; 4. *(излишество)* артыклык, артык тоту.

**РОСКО'ШЕСТВОВАТЬ** *несов.* — бик бай яшәү, байлык белән яшәү, зиннәт эчендә яшәү, муллыкка яшәү; артык зур расходлар белән тору.

**РОСКО'ШНИК** *м. разг. устар.* — зиннәтле тормыш яратучы, бик мул торуга һәвәс кеше; әрәм-шәрәм итүче, туздыручы, исрафчы.

**РОСКО'ШНИЧАТЬ** *несов. разг.* — к. роскошествовать.

**РОСКО'ШНО** *нареч.* — зиннәт белән, байлык белән; шәп, үкертеп; *жить раскошно* — шәп тормышта яшәү.

**РОСКО'ШНЫЙ** — 1. зиннәтле, купшы, нәзакәтле; асыл, гүзәл, күркәм, матур, шәп; *раскошное платье* — зиннәтле (асыл) күлмәк; *раскошный переплёт* — бик күркәм эшләнгән китап тышлыгы; 2. *(расточительный)* артык зиннәтле, артык мул, артык бай; түгеп-чәчеп...; артык күп расход тотып, сарыф итеп; *раскошный образ жизни* — артык зиннәтле тору; 3. *разг.* гаҗәеп матур, гаҗәеп шәп, менә дигән, иң яхшы, бик (һ)әйбәт; *роскошная погода* — бик шәп һава; 4. *разг. (изобильный)* һәрнәрсәгә бик бай, бик мул; ямьле, асыл, тормыш өчен уңай; *роскошный край* — ямьле як, һәрнәрсәгә бай як.

**РО'СКОШЬ** *ж. мн.* нет — 1. зиннәт(лелек), купшылык; шәп булу, асыл булу; *роскошь дамских платьев* — хатын-кыз күлмәкләренең купшылыгы (зиннәтлелеге); 2. артык зиннәт, артык муллык, артыклык; *ну, это уже роскошь* — ә бу инде бер дә кирәкмәгән артыклык; 3. иксез-чиксез байлык, муллык; гүзәллекләр; *роскошь южной природы* — көньяк табигатенең иксез-чиксез байлыклары ◇ **Что за роскошь купанье в море!** — диңгездә коену нинди шәп (нинди рәхәт)! **Позволить себе роскошь** — артыклыкка юл кую, артык күп тоту. **Жить в роскоши** — үкертеп яшәү, байларча тору.

**РО'СЛЫЙ** — 1. *(высокого роста)* озын буйлы, зур гәүдәле; буе озын, буйга зур; 2. *спец.* биек; *рослые деревья* — биек агачлар; 3. *обл. (заросший)* үлән баскан, куаклы, агачлы; ... белән капланган; *рослое место* — үлән баскан урын яки агачлы урын.

**РОСНИ'К** *м. бот.* — к. манжетка.

**РОСНИ'ЦА** *ж. бот.* — к. росянка.

**РО'СНО** *нареч. обл. в знач. сказ.* — чыклы, чык күп.

**РОСНО'Й, РО'СНЫЙ** I: **росной (росный) ладан** — хуш исле сумала (көньяк Азиядә үсә торган кайбер агачлар кабыгыннан алына).

**РО'СНЫЙ** II *обл.* — бик чыклы.

**РОСОМА'ХА** *ж. зоол.* — 1. росомаха, Себер бурсыгы (ерткыч җәнлек); 2. *перен. обл. пренебр. (неряха)* җобалгы, җебегән, әкрен кыймылдаучы.

**РОСОМА'ШИЙ** — росомаха (Себер бурсыгы)...-ы; росомаха мехыннан тегелгән; *росомаший мех* — Себер бурсыгы мехы.

**РОСОМЕ'Р** *м. метеор.* — чык үлчәгеч (күпме чык төшкәнен үлчи торган прибор).

**РО'СПАШЬ** *ж. обл.* — сөрү җире, сөрелгән җир, сукаланган кыр.

**РО'СПИСЬ** *ж.* — 1. *канц. (инвентарь, перечень)* исемлек, әйберләр исемлеге; дәфтәр (мәсәлән, керем-чыгым дәфтәре, исемлеге); 2. к. расписать 1; 3. *собир. живоп.* бизәк, рәсем, сурәт, нәкышь (йорт, бина диварларында).

**РО'СПИТЫЙ** *простореч.* — к. распитой.

**РО'СПЛЕСК** *м. мн.* нет — к. расплескать.

**РО'СПЛЫВЬ** *ж. мн.* нет, *спец.* — 1. (бүрәнәләрне) салга бәйләмичә агызу; аерым-аерым агызу; *гнать лес росплывью* — салга бәйләмичә агач агызу; 2. *собир.* салга бәйләнмәгән бүрәнәләр, аерым-аерым аккан бүрәнәләр.

**РО'СПУСК** *м.* — 1. *только ед.* к. распустить 1; 2. тарату (каникулга) чыгару, таратып җибәрү; кайтару; *роспуск учащихся*

*на каникулы* — укучыларны каникулга чыгару; *роспуск организации* — оешманы тарату; *роспуск армии* — армияне тарату (өйләргә кайтару); 3. *спец.* бәйләгән әйбердән сүтелгән җеп; 4. *спец.* к. росплывь.

**РО'СПУСКИ** *только мн.* — утын чанасы; утын арбасы.

**РОСС** *м. устар. поэт.-торж.* — рус, рус кешесе. россияле.

**РОССИ'ЙСКИЙ** *офиц.* — 1. *устар.* рус...-ы; *российский язык* — рус теле; 2. Россия...-ы; *история государства российского* — Россия дәүләте тарихы; *Российская Советская Федеративная Социалистическая республика* — Россия Совет Социалистик Федератив Республикасы.

**РОССИЯ'НИН** *м. старин. офиц. торж.* — россияле, русияле, рус кешесе, Россия гражданины.

**РОССИЯ'НКА** *ж. старин. офиц. торж.* — русияле хатын-кыз, рус хатын-кызы, Россия гражданкасы.

**РО'ССКАЗНИ** *ед.* нет, *разг. пренебр.* — юк-бар сүзләр, әкият, кеше ышанмаслык уйдырмалар, ялган сүзләр, сафсата.

**РОССОМА'ХА, РОССОМА'ШИЙ** — к. росомаха, росомаший.

**РО'ССТАНЬ** *ж. обл.* — чат, ике юл чаты, ике юл аермасы.

**РО'ССЫПЬ** *ж.* — 1. *простореч.* (*всё то, что рассыпано*) сибелмә, чәчелмә; сибелгән, чәчелгән әйбер; 2. *простореч.* к. рассыпать 1, 2, 3, 4, 5; 3. к. рассыпаться 1, 2; 4. *спец.* коелу, авырлыгы кимү (түгелеп-чәчелеп); 5. *горн.* казылма байлыклар чыга торган җир; *золотые россыпи* — алтын чыга торган җир; *алмазные россыпи* — алмаз чыга торган җир; 6. *перен.* (*изобилие*) байлык, күплек, муллык; бетмәс-төкәнмәс (иксез-чиксез) күп булу; 7. *геол.* ишелмә (тау токымы ишелмәләре).

**РОСТ** *м. мн.* нет — 1. к. расти; 2. (*процесс*) үсү, үсеп килү, җитлегү; *период роста организма* — организмның үсү чоры; 3. буй, гәүдә; *человек среднего роста* — урта буйлы кеше; 4. *перен.* (*развитие*) үсеш, алга китеш, алгарыш, күтәрелеш; *рост производства* — җитештерүнең үсеше; (*совершенствование*) үсү, камилләшә бару, осталык арту, җитлегә бару; 5. *перен.* кинәю, зураю; көчәю, ныгу; арту, күбәю; *рост влияния партии* — партия йогынтысының көчәюе; 6. *устар.* артым, үсем, процент; *дать деньги в рост* — акчаны процентка бирү. ◇ **Во весь рост** — 1) тураеп, бар буена баскан килеш; 2) *перен.* бөтен тулылыгы белән, кискен рәвештә, катгый итеп. **На рост** — үсәчәген искә алып (тегү). **Подавить ростом** — томалау, каплау, басып китү.

**РО'СТБИФ** *м. кулин.* — ростбиф (сыер итеннән кыздырып пешерелгән ашамлык, куырма; сыер түшкәсенең шундый ашамлык хәзерләү өчен китә торган сырт өлеше).

**РО'СТВЕРК** *м. тех.* — ростверк (көпшәк грунтны ныгыту өчен корылмалар, биналар астына салып калдырыла торган бетон яки тимер-бетон түшәлмә, нигез).

**РО'СТЕПЕЛЬ** и **РО'СТОПЕЛЬ** *ж. обл.* — (суыклардан соң) һава җылыту, көннәр җылыну, җепшек көн.

**РО'СТИТЬ** *несов.* — к. растить.

**РОСТКО'ВЫЙ** — 1. үргән, шыткан; үренте (тармак, ботак, сабак) җибәргән; *ростковая часть* — үргән өлеше, тармак җибәргән өлеше; 2. үрентелек.., утыртма(лык), утырта торган, бөреле; *ростковые черенки* — утырта торган сабаклар.

**РОСТОВО'Й** *спец.* — 1. үсү...-ы, үсеп җитлегү...-ы; үсем...-ы; *ростовая пора* — үсү чоры, үсеп җитлегү чоры; 2. (*способствующий росту*) үсешне тизләтүче, үсүне көчәйтүче; үстерә (уңдыра) торган; уңышны арттыручы, уңдырышны күтәрүче; *ростовые вещества* — үсешне тизләтүче матдәләр.

**РОСТОВЩИ'К** *м.*, **РОСТОВЩИ'ЦА** *ж.* — ростовщик, процентка бирүче, рибачы (мохтаҗ кешеләргә процент белән бурычка акча биреп торып, шуннан килгән файда исәбенә зур табыш алучы).

**РОСТОВЩИ'ЧЕСКИЙ**: **ростовщический капитал** — процентка бирелә торган капитал; **ростовщические проценты** — процентка бирүдән килгән файда.

**РОСТОВЩИ'ЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.* — ростовщиклык, процентка акча бирү, рибачылык.

**РОСТОВЩИ'ЧИИ** *разг.* — к. ростовщический.

**РОСТО'К** *м.* — 1. бәбәк, кечкенә үренте (орлыкның үрә башлаган яралгысы, күзе); *семя дало росток* — орлык кечкенә үренте чыгарган; 2. (*о посеянном*) шытым, үсенте (яңа тишелгән үсемлек); *семя пустило росток* — орлык шытым чыгарган, орлык тишелеп чыккан; 3. *сад.* (*посадочный материал*) ботак, тармакчык; үсенте, үренте (утырту өчен бөреле сабак кисәге); 4. *перен. книж.* башлангыч билге, беренче эз; яралгы; *первые ростки революции* — революциянең башлангыч билгеләре.

**РОСТОМЕ'Р** *м. спец.* — буй үлчәгеч.

**РО'СТРА** *ж.* — ростра (1. *истор.* борынгы Римда ораторлар трибунасы; 2. *архит.* борынгы корабльләр борынына охшатып колонналарга эшләнгән бизәк; колонналар өстендәге нәкышьләр; 3. *мор. только мн.* корабль бортында көймә урнаштыру өчен махсус җайланма).

**РОСТРА'ЛЬНЫЙ** *архит.*: **ростральные колонны** — ростраль колонналар, ростраль колонналар (әүвәлге сугыш корабльләре борынына охшатып эшләнгән колонналар).

**РО'СЧЕРК** *м.* — 1. (*завиток в конце подписи*) кул куйгач боргалап җибәрү; боргалап куелган имза; имза койрыгы; 2. (*завиток буквы*) хәреф койрыгы, боргалап-сыргалап язылган хәреф. ◇ **Одним росчерком пера (решать)** *перен.* — бик ашыгыч, дуамал, эшнең асылына төшенеп тормастан, бер сызу белән (хәл итү).

**РОСЧЕРКНУ'ТЬ** *сов. разг.* — боргалап-сыргалап сызып җибәрү, боргалап-сыргалап имза кую.

**РО'СЧИСТЬ** *ж. с.-х. обл.*— ышна, арчылган җир, төпләгән җир.

**РОСЯ'НКА** *ж. бот.* — чыклы үлән (яфраклары өстенә ябышкак лайла чыгарып шуңа кунган бөҗәкләрне ашаучы үсемлек).

**РОСЯНО'Й, РОСЯ'НЫЙ** — 1. чык...-ы; *росяная капля* — чык тамчысы; 2. чык белән..., чыкта...; *росяная мочка льна* — җитенне чык белән чылату, чыкта чылату.

**РОТ** *м.*— 1. авыз; *прополоскать рот* — авыз чайкау; 2. *перен. простореч.* (*едок*) җан, тамак, кеше; *мне надо семь ртов прокормить* — миңа җиде җанны туйдырырга кирәк. ◇ **Мимо рта** (прошло, пролетело) *шутл.*— ашарга туры килмәде, алырга туры килмәде. **В рот не попало**—авызга кермәде, йокмады. **Рот открыть (раскрыть)** *разг. перен.*— авыз ачып сүз әйтү, җавап бирү, әйтеп бетерү; *он не даёт никому рта открыть* — ул беркемгә сүз әйтергә дә бирми. **В рот нейдёт** *разг.* — тамактан үтми, тамакка бармый, бик тук. **В рот не возьмёшь** *разг.*— авызга да алырлык (кабарлык) түгел; тәмсез, ашарлык түгел. **Разинуть рот** *разг. ирон.*— авыз ачып карап тору, шаккату, ис китү. **Не сметь рта разинуть** (раскрыть, открыть) *разг. перен.*— авыз ачып сүз әйтергә куркып тору. **Во весь рот** (орать) — бик каты (кычкыру, бугаз ниерү, бакыру). **Хлопот полон рот** — мәшәкать бик күп, эш муеннан. **Разжевать и в рот положить** *разг. ирон. перен.*— авызына чәйнәп каптыру (җентекләп аңлатып бирү). **Смотреть в рот** — 1) ашаган кешенең авызына карап тору (саранлыктан); 2) *перен.* (сөйләгән) кешенең авызына карап тору; ялагайлану, ярарга тырышу. **Зажать (заткнуть) рот** — авызын каплау, авызын томалау (сөйләргә ирек бирмәү, туктату). **Не брать в рот** — авызга да алмау; *хмельного он и в рот не берёт*— аракыны ул авызына да алмый. **Взять в рот** — кабу.

**РО'ТА** *ж. воен.*— рота (батальон составындагы гаскәри берәмлек). ◇ **Арестантские роты** *истор.*— арестант роталары (тоткыннарны мәҗбүри эшләтү өчен махсус төркемнәр). **Золотая рота** *просторец.устар.*— 1. алтын укалы рота (патша сарайларын саклаучы махсус гаскәр, гренадёрлар); 2. *перен.* арестантлар, сукбайлар.

**РОТА'ТОР** *м. тех.*— ротатор (сызым, кулъязма һәм рәсемнәрне бастырып күбәйтү җайланмасы).

**РОТАЦИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *науч.* — ротацизм (1. „р" авазын сакау әйтү; 2. „р"лаштыру, „з" авазы урынына „р" куллану, мәсәлән, менгез — менгер һ. б. ш.).

**РОТАЦИО'НКА** *ж. просторец. спец.*— к. ротационная машина.

**РОТАЦИО'ННЫЙ: ротационная машина** *полигр.* — ротацион машина (газета һәм китапларны күпләп басу машинасы).

**РОТА'ЦИЯ** *ж.*— 1. *полигр.* ротация, ротацион машина; 2. *спец.* (*круговращение*) әйләнеш, әйләнү, түгәрәк буенча әйләнеш, ротация.

**РО'ТМИСТР** *м. дореғол.* — ротмистр (1. элекке Россиядәге атлы гаскәрнең эскадрон командиры; 2. жандармериядә офицер чины).

**РО'ТМИСТРША** *ж. разг. дореgол.*— ротмистр хатыны.

**РО'ТНЫЙ** *воен.*— 1. рота...-ы; *ротный командир* — рота командиры; 2. *в знач. сущ. м. разг.* рота командиры.

**РОТОВО'Й** — авыз...-ы; *ротовая полость* — авыз куыш(лыг)ы.

**РОТОЗЕ'Й** *м.*, **РОТОЗЕ'ЙКА** *ж. разг. неодобр.*— игътибарсыз (таркау, җобалгы) кеше; байгыш, аңгыра; ачык авыз, эшкә җавапсыз (салкын, гамьсез) караучы, ваемсыз кеше.

**РОТОЗЕ'ЙНИЧАТЬ** *несов. разг. неодобр.* — ачык авыз булу, игътибарсызлык күрсәтү; эшне булдыра алмау, җебеп йөрү, авыз ачып йөрү.

**РОТОЗЕ'ЙСТВО** *ср. мн.* нет, *разг. неодобр.*—ачык авызлык, игътибарсызлык; таркаулык; аңгыралык, җавапсызлык, гамьсезлек, ваемсызлык, эшкә салкын карау.

**РОТО'К** *м. разг. фам.*— к. рот. ◇ **На чужой роток не накинешь платок** — кеше авызына йозак салып булмый.

**РОТО'НДА** *ж.* — ротонда (1. *архит.* гөмбәзле, түгәрәк яки ярым түгәрәк бина; 2. хатын-кызларның җиңсез тышкы җылы киеме).

**РОТОПРИ'НТ** *м. тех. тип.*— ротопринт, офсетлы ротатор (хезмәт кәгазьләре, документлар, реферат, бюллетень һ. б. ш. кебекләрне аз тиражда бастыру машинасы).

**РО'ТОР** *м. тех.*— ротор (1. электр машиналарының, су турбиналарының һәм нефть бораулау машиналарының әйләнә торган өлеше; 2. *мор.* судноларны җил ярдәмендә хәрәкәтләндерү өчен хезмәт итә торган, вертикаль куелган трубалардан гыйбарәт җайланма).

**РО'ТОРНЫЙ** *тех.* — ротор белән...; роторлы, әйләнмәле; *роторное судно* — роторлы судно; *роторное бурение* — ротор белән бораулау.

**РО'ХЛЯ** *м.* и *ж. разг. пренебр.* — йомшак (мәлҗегән, акрын кыймылдаучан, авыр сөякле) кеше; пешмәгән, җебегән, булмаган кеше.

**РО'ЩА** *ж.*— 1. кечкенә урман; урманчык, агачлык; 2. урман участогы, урман бүлемтеге. ◇ **Берёзовая роща** — каенлык, каенсар. **Дубовая роща** — имәнлек, туйралык. **Яблоневая роща** — алмалык. **Тальниковая роща** — таллык, таллы әрәмә.

**РОЩЕ'НИЕ** *ср. обл.*— к. ращение.

**РО'ЩИЦА** *ж.*— к. роща.

**РОЯЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *полит.*— роялизм (монархизм яклы булу, король хакимлеге яклы булу).

**РОЯЛИ'СТ** *м.*, **РОЯЛИ'СТКА** *ж. полит.*— роялист, монархист, роялизм тарафдары, монархияне яклаучы (Көнбатыш Европада король хакимлеген яклаучы кеше).

**РОЯЛИ'СТСКИЙ** *полит.* — роялизмны (монархияне) яклау...-ы; роялистларча, роялизм рухындагы; роялистлык...-ы; *роялист-*

*ские взгляды* — роялистлык карашлары, монархияне яклау карашлары.

РОЯ'ЛЬ *м.*— рояль (музыка коралы).

РСДРП (Российская Социал-Демократическая Рабочая Партия) *истор.*— РСДРП (Россия Социал-Демократик Эшчеләр Партиясе; Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең VII съездга кадәрге исеме).

РСФСР (Российская Советская Федеративная Социалистическая Республика) — РСФСР (Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы).

РТА'ЧИТЬСЯ *несов. обл.*— к. артачиться.

РТУ'ТИТЬ *несов. спец.*— к. нартучивать.

РТУ'ТНЫЙ — терекөмеш...-ы; *ртутные соединения* — терекөмеш кушылмалары.

РТУТЬ *ж. мн.* нет — терекөмеш, күнә суы.

РУБА'КА *м.*— (кылыч, сөңге һ. б. ш. кебек салкын корал белән) оста сугышучы; батыр, житез кеше.

РУБА'НОК *м.*— ышкы, струг.

РУБАНУ'ТЬ *сов. простореч.*— к. рубнуть.

РУБА'ТЬ *несов. обл.* и *спец.*— к. рубить.

РУБА'ХА ж.— к. рубашка 1. ◇ Рубаха-парень *разг. фам.*— ачык чырайлы кеше, эчкерсез кеше, эчендәгесе тышында булган кеше.

РУБА'ШЕЧНЫЙ — күлмәк...-ы; күлмәклек...; *рубашечная пуговица* — күлмәк сәдәбе; *рубашечная ткань* — күлмәклек тукыма.◇ Рубашечное *в знач. сущ., ср. обл.*— күрем, айлык, менструация.

РУБА'ШКА *ж.* — 1. күлмәк, ирләр күлмәге; *сатиновая рубашка* — сатин күлмәк; 2. *спец. (масть)* төс; *рубашка собаки* — этнең төсе; 3. *спец.* уен картасының кире ягы, арт ягы; 4. *спец. (оболочка плода в утробе)* бала күлмәге, яры, пәрдә; 5. *тип.* өске тышлык (каты тыш өстеннән тышлаган кәгазь); 6. *спец. тех.* юка катлау, катлам; *глиняная рубашка* — бер кат юка балчык катлавы (куыш металл әйберләр кою өчен балчыктан ясалган форма). ◇ Родиться в рубашке *разг. перен.* — бәхете (ризыгы) белән туу. Оставить в одной рубашке *разг.* — шәрә (ялангач) калдыру, бөлдерү, хәерчелеккә калдыру. Остаться в рубашке — күлмәкчән (күлмәктән) генә калу.

РУБАШО'НКА *ж. уничижит. разг.* — күлмәк кисәге, алама күлмәк.

РУБЕ'Ж *м.* — 1. *(граница)* чик, дәүләт чиге, чик сызыгы; 2. *перен. книж.* ара, урта, чик; *на рубеже двух эпох* — ике дәвер арасында; 3. *обл. (метка, зарубка)* тамга, билге, кирт; 4. *воен.* оборона сызыгы, оборона линиясе, ныгытма (оборона линияләре үткән буй, полоса); 5. *только ед. обл.* к. рубить. ◇ Водный рубеж — су (елга, диңгез) буйлап үткән дәүләт чиге. За рубежом — чит илләрдә. Остаться за рубежом истории — тарих тышында калу, тарихтан төшеп калу (читтә калу).

РУБЕ'ЛЬ *м. спец.* — 1. сырлы бәләк, кырлы тукмак (кер тәгәрәтү өчен); 2. *обл.* бастырык, йөк бастырыгы (салам, печәнне тарттырып бәйләү өчен).

РУБЕРО'ИД *м. тех.* — руберойд (түбә ябу һәм изоляцияләү өчен китә торган, утка чыдам материал).

РУБЕРО'ИДОВЫЙ *тех.* — руберойд...; руберойдтан ясалган; *руберойдовая изоляция* — руберойд изоляция.

РУБЕ'Ц I *м.* — 1. *(с. ед от раны)* җөй, төзәлгән яра урыны, җәрәхәт эзе; *рубец от шашки* —кылыч белән чапкан эз; 2. *(шов)* җөй, теккән урын; 3. *обл. (кромка)* чит, кайма (әйбернең берәр нәрсә тотылган кырые).

РУБЕ'Ц II *м.* — 1. *(у жвачных)* кырык карта́ (күшәүче хайваннар ашказанының бер өлеше); 2. *кулин.* пешкән карта́ (ашамлык).

РУБИ'ДИИ *м. хим.* — рубидий (химик элемент; көмешсыман ак төстәге йомшак металл).

РУБИКО'Н: перейти Рубикон *книж. перен.* — Рубиконны кичү, Рубикон елгасын кичү (катгый хәрәкәт итү, хәлиткеч адым атлау).

РУБИ'ЛЬНИК *м. тех.* — рубильник, өзгеч (электр тогын тоташтыра яки өзә торган җайланма).

РУБИ'Н *м.* — рубин, кызыл якут (асылташ); *кольцо с рубином* — якут кашлы йөзек.

РУБИ'НОВЫЙ — 1. якут..., якуттан эшләнгән, якут кашлы; *рубиновое ожерелье* — якут муенса; *рубиновое кольцо* — якут кашлы йөзек; 2. кызыл-кучкыл, кара-кызыл; якут төсле, рубин төсле.

РУБИ'ТЬ *несов.* — 1. чабу, кисү; чапкалау, тапау, тура(кла)у; *рубить мясо* — ит чабу, ит чапкалау; *рубить дрова* — утын кисү, утын вату (балта белән); *рубить лес* — урман кисү, агач кисү (кисеп аудару); 2. *воен.* (дошманны) кыру, тураклау, чабу; *рубить шашкой неприятеля* — кылыч белән дошманны чабу, дошманны кыру; 3. *разг. перен. (говорить, действовать резко)* артык катгый (кискен) эш итү, өзеп әйтү, кырт кисү; 4. *спец.* бура бурау; *рубить избу* — бура бурау (өй салу). ◇ Рубить с плеча *перен.* — 1) туп-туры әйтү; 2) кискен һәм дуамал эш итү. Рубить сучья (ветви) *спец.* — ботакларын чабып кәүсәне чистарту (ботау). Рубить всех вкривь и вкось — барысын тетеп салу, барысының тетмәсен тетү. Лес рубят—щепки летят *послов.* — урман кискәндә йомычкасыз булмый.

РУБИ'ТЬСЯ *несов.* — (кылыч, хәнҗәр белән) сугышу, чабышу, кисешү.

РУ'БИЩЕ *ср. мн.* нет — 1. *(ветхая одежда)* начар кием, иске кием, сәләмә кием; 2. *старин.* киндер күлмәк, алача күлмәк.

РУ'БКА I *ж. мн.* нет — к. рубить 1.

РУ'БКА II *ж.* — рубка (1. корабльләрнең палубаларында була торган аерым бүлмә; 2. нинди дә булса махсус бер эш өчен билгеләнгән бүлмә, мәсәлән, радиорубка).

РУБЛЁВИК *м.*, РУБЛЁВКА *ж. разг.* — бер сумлык акча, бер тәңкә (кәгазь яки көмеш акча).

**РУБЛЁВЫЙ** — бер сумлык, бер тәңкәлек; *рублёвый билет* — бер сумлык билет.

**РУ'БЛЕНЫЙ** — 1. туралган, чапкан, туракланган, тапалган; *рубленое мясо* — чапкан ит; 2. чапкан иттән хәзерләнгән; *рубленые котлеты* — чапкан иттән хәзерләнгән котлет; 3. буралган, бурап салынган; бүрәнәләрдән салынган, агач...; *рубленая изба* — агач өй, бүрәнәләрдән салынган өй.

**РУБЛЬ** *м.* — 1. (бер) сум, (бер) тәңкә; *ценою в два рубля* — ике сумлык, ике тәңкә тора торган; 2. *перен.* акча, сумнар; *советский рубль* — совет акчасы, совет сумнары. ◇ **Рублём подарит** *нар.-поэт.* — кояш чыккандай, тулган ай кебек; *посмотрит — рублём подарит* — ул күтәрелеп караса, кояш чыккандай була, керфегеннән гөлләр тама. **Длинный рубль** — к. длинный. **Не рублём, так дубьём** — аш белән булмаса, таш белән (алдыра).

**РУБНУ'ТЬ** *сов. разг. однокр.* — 1. к. рубить; 2. бер кисү, бер чабу; кисеп алу, чабып кую, чабып (кисеп) чыгару; кыеп төшерү.

**РУ'БРИКА** *ж.* — 1. *(заголовок)* баш, исем; рубрика; *под рубрикой* „На новом строительстве“ — „Яңа төзелештә“ дигән баш астында; 2. бүлем, бүлекчә; графа; *разнести данные по соответствующим рубрикам* — мәгълүматларны тиешле графаларга язып кую.

**РУБРИКА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *книж.* — бүлекләргә бүлү; бүлекләргә бүленеш.

**РУБЦЕВА'НИЕ** *ср. мн.* нет — к. рубцеваться.

**РУБЦЕВА'ТЫЙ** *разг.* — бик күп жөйле, жөйле-жөйле; киселеп беткән; жөйләр (жәрәхәт эзләре) белән капланган (тән, йөз).

**РУБЦЕВА'ТЬСЯ** *несов.* — (яра жөйләнеп) төзәлү, йомылу, ялгану.

**РУ'БЧАТЫЙ** — 1. *(рубцеватый)* жөйле, жөйле-жөйле, жөйләр белән капланган; 2. кытыршы, сырлы-сырлы; *рубчатая ткань* — сырлы-сырлы тукыма.

**РУ'БЧИК** *м.* — 1. к. рубец I; 2. *(выпуклая полоска на ткани)* сыр, буй-буй сыр, кытыршылык.

**РУ'ГАНЬ** *ж. мн.* нет — әшәке сүзләр, сүгенү сүзләре; сүгеш, тиргәш; хурлау сүзләре.

**РУГА'ТЕЛЬ** *м.* — бик яман сүгенүче; әшәке сүзле, әшәке телле; хурларга яратучы.

**РУГА'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. сүгенү (сүгешү) ...-ы; хурлау...-ы; әшәке, сүгеп (орышып) әйтелгән; *ругательные слова* — сүгенү сүзләре; 2. *разг.* начар, кире, тискәре; *дали ругательный отзыв* — тискәре бәя биргәннәр.

**РУГА'ТЕЛЬСКИ: ругательски ругать** — бик нык (каты) сүгү, хурлау.

**РУГА'ТЕЛЬСТВО** *ср.* — сүгенү сүзләре, әшәке сүзләр.

**РУГА'ТЬ** *несов.* — 1. сүгү, тиргәү, әрләү, орышу; 2. хурлау, мәсхәрәләү.

**РУГА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. сүгенү, әшәке сүзләр әйтү; 2. *(ссориться)* тиргәшү, әрләшү, орышышу, кычкырышу, әйткәләшү, телләшү; ызгышу, талашу; 3. *(надругаться, издеваться)* хурлау, сүгү, мыскыл итү, мыскыллау.

**РУГНУ'ТЬ** *сов. разг. фам.* — әз генә сүгеп алу, тиргәп (әрләп) алу, орышып алу; тиргәп ташлау, сүгеп ташлау, орышып кую.

**РУГНУ'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.* — сүгенеп алу, сүгенеп жибәрү, оятсыз сүз әйтеп жибәрү, әшәке сүз әйтеп ташлау.

**РУГНЯ'** *ж. мн.* нет, *простореч.* — к. ругань.

**РУГОТНЯ'** *ж. мн.* нет, *простореч.* — 1. к. ругань; 2. шау-шу, гауга, низаг; *руготню поднимать* — гауга күтәрү.

**РУДА'** *ж.* — 1. руда, мәгъдән (металлы тау токымы); 2. *старин.* кан.

**РУДИМЕ'НТ** *м.* — рудимент (1. *биол.* организмның эволюцион үсеше нәтиҗәсендә үзенең әһәмиятен югалткан калдык әгъза, мәсәлән, кешенең сукыр эчәк үсентесе, койрык сөяге һ. б. ш.; 2. *книж.* калдык күренеш, калдык эзләр, калдык билгеләр; бетеп бара торган күренешләрнең калдыгы).

**РУДИМЕНТА'РНЫЙ** *книж.* — рудиментар, житлекмәгән, яралгы хәлендәге, үсеп житмәгән; калдык, борынгыдан калган; *рудиментарные органы* — житлекмәгән әгъзалар; рудиментар (калдык) әгъзалар.

**РУДНИ'К** *м.* — рудник (руда чыгарыла торган урын).

**РУДНИКО'ВЫЙ** и **РУДНИ'ЧНЫЙ** — 1. рудниктагы, рудник...-ы; *рудниковый газ* — рудник газы, рудниктагы газ; *рудничная крепь* — рудник ныгытмалары (терәкләре); 2. рудникта кулланыла торган; *рудничная лампа* — рудникта кулланыла торган лампа.

**РУ'ДНЫЙ** — руда...-ы; рудалы, руда чыга торган, руда хәлендәге; *рудные ископаемые* — руда хәлендәге казылма байлыклар; *рудные месторождения* — рудалы урыннар, руда ятмалары.

**РУ'ДНЯ** *ж. старин.* — примитив рудник (бакыр базы, тимер базы һ. б. ш. кебекләр).

**РУДО'ВЫЙ** *обл.* и *спец.* — бик чыдам, бик каты, бик нык, коры жирдә үскән; *рудовая сосна* — бик каты нарат.

**РУДОЖЁЛТЫЙ** — кызгылт-соры, жирән, куе сары.

**РУДО'Й** *обл.* — кызыл, кызгылт-сары, жирән.

**РУДОКО'П** *м.* — рудокоп, руда казучы; рудник эшчесе, рудникта эшләүче.

**РУДОКО'ПНЫЙ** — руда казу...-ы; *рудокопное дело* — руда казу эше.

**РУДОНО'СНЫЙ** — рудалы, рудасы булган, рудага бай; *рудоносный слой* — рудалы катлау.

**РУДОПОДЪЁМНЫЙ** *горн.* — руда чыгара торган, руда ташый торган, руда күтәрү ...-ы; *рудоподъёмные машины* — руда күтәрү машиналары.

**РУДОПРОМЫ'ВОЧНЫЙ** *горн.* — руда юу ...-ы; руданы су белән юдыра торган, руда

чистарта торган; *рудопромывочные установки* — руда юу җайланмалары.

**РУДОУПРАВЛЕ'НИЕ** *ср.* — рудник идарәсе; рудниклар идарәсе.

**РУДЯ'К** *м. спец.* — рудяк (комның тимер окисе һәм черемә белән керешүеннән туфракта барлыкка килгән аз тимерле таш катлавы).

**РУЖЕ'ЙНИК** *м.* — 1. *старин. (воен.)* мылтыклы, мылтыклы сугышчы; 2. *(мастер)* мылтык ясаучы, мылтыкчы, мылтык остасы; мылтык заводы эшчесе.

**РУЖЕ'ЙНЫЙ** — мылтык...-ы; *ружейные выстрелы* — мылтык атышлары; *ружейный мастер* — мылтык остасы; *ружейный ремень* — мылтык каешы; 2. мылтык белән...; *ружейная охота* — мылтык белән сунарчылык итү. ◇ **Ружейная собака** — ау эте (мылтык авына алып йөри торган эт).

**РУЖЬЁ** *ср.* — мылтык. ◇ **В ружьё стать** *воен.* — стройга (сафка) басу. **Призвать под ружьё** — хәрби хезмәткә чакыру, хәрби хезмәткә (солдатка) алу. **Поставить под ружьё** *воен. устар.* — солдатны мылтык астына бастыру (барлык корал һәм кирәкяракларын күтәрткән хәлдә смирно тоту — патша гаскәрендә җәза бирүнең бер төре). **Быть (находиться) под ружьём** — 1. *(служить)* армиядә хезмәт итү, гаскәри хезмәттә булу; 2. *(на боевом положении)* хәрби хәзерлек хәлендә тору.

**РУЖЬИ'ШКО** *ср. разг. уничижит.* — мылтык кисәге, начар гына мылтык, алама мылтык.

**РУИ'НА** *ж.* — 1. *чаще мн. (развалины)* җимереклек, хәрабә (гадәттә җимерек бина, борынгы шәһәр калдыклары); 2. *перен. разг. шутл. (престарелый человек)* бик карт кеше, картаеп таушалган кеше, какшаган кеше.

**РУИНИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книжн. редко* — җимерү, җимереккә әйләндерү, хәрабәгә әйләндерү.

**РУКА'** *ж.* — 1. кул; *левая рука* — сул кул; 2. *перен.* кул, кеше, эшче, эшләүче; *мало свободных рук* — буш эшчеләр аз, буш куллар аз; *дело в опытных руках* — эш тәҗрибәле кешеләр кулында, тәҗрибәле кулларда; 3. *(почерк)* кул, язу, почерк; *это не моя рука* — бу минем кулым түгел, бу минем язу түгел; *неразборчивая рука* — танылмый торган почерк; 4. *(подпись)* имза, кул; *подделать чью-н. руку* — берәүнең имзасына охшатып кул кую; *руку приложить* — кул кую, имза кую; 5. *перен. только ед. разг.* үз кеше, химаяче, яклаучы, таянычы; *у него там своя рука* — аның анда үз кешесе бар (ярдәм итәр кешесе бар); 6. *разг. (сторона)* як, тараф, кул, юнәлеш; *по правую руку* — уң якка (уң кулга) таба; 7. *разг. устар.* сыйфат, сорт, дәрәҗә, төр; *мука первой руки* — беренче сорт он. ◇ **Просить чьей-либо руки** — берәүнең кулын сорау (кияүгә чыгуын үтенү, никахка ризалыгын сорау). **Предложить руку и сердце** — кияүгә чыгарга тәкъдим итү. **Много женихов искали её руки** — бик күп егетләр аны алырга йөрделәр. **Отдать кому-н. свою руку** — кияүгә чыгарга ризалык бирү; берәүгә бару, тормышка чыгу. **Плут большой руки** — ата хәйләкәр, ашып киткән хәйләкәр. **Наложить на что-н. руку** — (берәр әйбергә) ия булып алу, эләктерү, кул салу, басып алу. **Прибрать к рукам** — 1. *(что)* үзләштерү, үзенеке итү; 2. *(кого)* буйсындыру, каты тоту. **Валится из рук** *разг.* — кул бармый (эшкә), эшләнми, эшләп булмый. **Волю давать рукам** *разг.* — сугышу, кулны озындыру, кулга ирек бирү. **Голой рукой не тронь** — к. голый. **Голыми руками брать** — к. голый. **Греть руки** — к. греть. **Дать по рукам** *разг. фам. перен.* — акылга утырту, арт сабагын укыту (кирәген биреп биздерү). **Давать руку на отсечение** *перен.* — кулны кисәргә бирү (ант итеп ышандыру). **Держать руку** *перен.* — яклау, яклап сөйләү, ягында тору, ярдәм күрсәтү. **Не доходят руки** *разг.* — кул җитми, вакыт (мөмкинлек) юк. **Живой рукой** — бик тиз, кызуында. **Из рук вон (плохо)** *разг.* — бик начар, бернигә тормый, бернәрсәгә дә ярамый. **Из рук в руки или с рук на руки** (передать и др.) — кулдан кулга, турыдан-туры, арадашчыдан башка. **Как рукой сняло** — бернәрсәсе калмады, эзе дә калмады. **Как без рук** *разг.* — бөтенләй кулсыз калгандай булу, ярдәмчесез калу, берни эшли алмау. **Коротки руки** *разг. фам.* — кулың кыска (көчең җитмәс, булмас). **Ломать руки** *перен.* — бик нык кайгыру, кайгыга бату, өметсезлеккә төшү. **Мастер (мастерица) на все руки** — һәр эш кулыннан килә, барысын да эшли белә. **Махнуть рукой на кого-что** — к. махнуть. **Набить руку** *разг.* — кулы шомару, күнегү, өйрәнү, остарып җитү. **На руку** *кому разг. перен.* — берәү өчен уңайлы, бик шәп, кулай, кул килә, туры килә. **На руку нечист** *разг. фам.* — урлаучан, кулы тик тормый. **Не дрогнет рука (сделать)** — к. дрогнуть. **Не поднимается рука** *разг.* — кул(ы) күтәрелми, кул бармый. **Не положить рук** *книжн.* — ...-ганчы (мыйча) тынычланмау, туктамау. **Не покладая рук** — армый-талмый. **Не рука** *кому прострем.* — уңайсыз, ярамый, урынсыз, вакытсыз. **Обеими руками подписаться** *разг. перен.* — дүрт куллап, бик теләп, бик килешеп риза булу. **Обеими руками ухватиться** *разг. перен.* — дүрт куллап каршы алу, шатланып килешү. **Опускаются (отнимаются) руки** *разг. перен.* — берни эшлисе килми, куллар тыңламый (кайгыдан, өметсезлектән һ. б.). **От рук отбиться** *разг.* — тыңламый башлау; үз эшен үтәми башлау, буйсынмый башлау, баш ими башлау. **От руки (написать)** — кулдан (язу). **Охулки на руку не положить (класть)** — к. охулка. **Подать руку помощи** *перен.* — ярдәм кулы сузу. **Поднять руку** *перен.* — 1. кул күтәрү (берәр кешене үтерергә яки аңа сугарга теләү, һөҗүм итү); 2. сугыш, көрәш башлау. **Под руки** — култыклап, култыклашып. **Под рукой** *разг.* — 1) *устар.* болай гына, җае туры килеп, узышлый, үтешли; 2) янында, кырыенда гына, кул

астында; *нужной книги не оказалось под рукой* — кирәкле китап янымда булмады. **По́д руку** — 1) *перен.* комачаулау, кул астына керү; *не суйся под руку* — комачаулама әле, тыгылма әле; 2) култыкла(шы)п. **Попался ему под сердитую руку** — аның ачулы вакытына эләкте. **Под весёлую руку** — кәефе килеп; *под весёлую руку расплясались* — кәефләре килеп биергә тотындылар. **По рукам бить (ударить)** *перен.*— ризалашу, кул сугып килешү. **По рукам ходить** — таралу, кулдан-кулга йөрү. **По руке** — кулга ипле, җайлы, кулга туры килә, тотарга уңайлы. **Правая рука** *перен.* — беренче ярдәмче, ышанычлы, таяныч, уң кулы. **Приложить руку** *перен.* — катнашу. **Протянуть руку** *разг. устар. перен.* — сәдака сорый башлау, хәер сорашып көн күрү, чат башында тору. **Рука об руку** — кулга кул тотышып, бергәләшеп, дус булып, бердәм рәвештә, тату рәвештә. **Развязать руки** *перен.* — кулын чишү, ирек бирү. **Руки прочь** *ритор.* — кулыңны ал, кагылма, катнашма, тыгылма. **Рукой подать** *разг.* — кул сузымы җир, бик якын, күршедә (янәшә) генә. **Сон в руку** *разг.* — төшем дөрескә чыкты (рас килде). **С рук долой** — өстән төшү, котылу. **С рук сойти** — җәзасыз үтү (берәр җинаятьле эш турында). **С рук торговать** *спец.* — кулдан сату итү. **С руками оторвать** *разг. перен.* — кулдан тартып алу (бик теләп сатып алу). **С руки** *разг.* —1) кул(ай), ипле, урынлы, туры килә, уңай; 2) җинел кулдан; *ты с моей руки разжился* — син минем җинел кулдан баедың. **Умыть руки** *книж. перен.* — читләшү, җаваплылыктан качу, өстенә алмау. **Чешутся руки** *разг.* — кул кычыта (сугышасы килә, эшлисе килә). **В чужих руках ломоть всегда толще** — күрше тавыгы күркә булып күренә. **Ему это дело не рука** — аңар бу эш төс түгел. **Длинные руки** *перен.*— озын куллы (урлашучан, әйбергә тиючән). **Не по руке** — ярамый, сыймый; *перчатки не по руке* — бу перчатка миңа ярамый (зур яки кечкенә). **Сбыть с рук**— олактыру, этеп-төртеп бирү. **Отдать в руки** — тапшыру, үз кулына бирү.

**РУКА'В** *м.*— 1. җиң; *засучить рукава* — җиң сызгану; 2. тармак; *рукав реки* — елга тармагы; 3. *тех.* насос эчәгесе, шланг, труба; *резиновый рукав* — резин эчәк, резин шланг. ◇ **Спустя рукава работать** — эленке-салынкы эшләү, җиренә җиткермичә эшләү; миннән киткәнче, нясенә җиткәнче, дип эшләү.

**РУКАВИ'ЦА** *ж.*— бияләй; *кожаные рукавицы* — күн бияләй ◇ **Держать в ежовых рукавицах** — каты тоту, авызлыклап тоту.

**РУКАВИ'ЧНИК** *м.*— бияләй тегүче оста.

**РУКА'ВНЫЙ** *спец.*— җиңлек..., җиң...-ы; *рукавная подкладка* — җиң эчлеге, җиңлек астар.

**РУКА'ВЧИК** *м.*— 1. *разг. фам.* к. рукав; 2. (*нарукавник*) җиңсә, җиң очы, манжет.

**РУКА'СТЫЙ** *простореч.*— 1. озын куллы, юан куллы; 2. *перен.* кәкре куллы, озын куллы, әйбергә тия торган, урлаша торган.

**РУКОБИ'ТЬЕ** *ср. истор.*— 1. килешү, (кул сугып) ризалык бирү; 2. *устар. (свадебный обряд)* ярәшү, ризалашу, ризалык бирү (ике якның ата-анасы килешү).

**РУКОБЛУ'ДИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— к. онанизм.

**РУКОБЛУ'ДНИК** *м.*, **РУКОБЛУ'ДНИЦА** *ж. книж. устар.*— онанизм белән шөгыльләнүче.

**РУКОБЛУ'ДНИЧАТЬ** *несов. книж.*— онанизм белән шөгыльләнү.

**РУКОВО'Д** *м. разг.*— к. руководитель.

**РУКОВОДИ'ТЕЛЬ** *м.*— 1. җитәкче; *партийный руководитель* — партия җитәкчесе; *классный руководитель* — класс җитәкчесе; 2. башлык, мөдир, ... башында торучы; *руководитель отдела* — бүлек мөдире, бүлек башлыгы.

**РУКОВОДИ'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет, *книж. устар.*— җитәкчелек, җитәкчелек итү, җитәкчелек эше.

**РУКОВОДИ'ТЕЛЬСТВОВАТЬ** *несов. книж. устар.*— баш булу, башлык булу, җитәкчелек итү.

**РУКОВОДИ'ТЬ** *несов.*— 1. җитәкчелек итү; юл күрсәтү, юнәлеш бирү; *руководить рабочим движением* — эшчеләр хәрәкәтенә җитәкчелек итү; 2. *офиц. канц.* идарә итү, мөдир булу, (эшнең) башында тору, җитәкчелек итү; *руководить колхозом* — колхоз белән идарә итү, колхоз белән җитәкчелек итү.

**РУКОВОДИ'ТЬСЯ** *несов. книж.*— 1. кулланy, таяну, кулланып эш итү; ...-дан чыгып эш итү; *мы руководимся заветами Ленина* — без Ленин васыятьләрен кулланып эш итәбез; 2. *страд.* җитәкчелек ителү, идарә ителү.

**РУКОВО'ДСТВО** *ср.*— 1. к. руководить, руководиться; 2. *только ед.* җитәкчелек, җитәкчелек эше; башлык булу, җитәкче булу; 3. *(пособие)* кулланма, белешмәлек; *марксизм — не догма, а руководство к действию* — марксизм догма түгел, ә эш өчен кулланма; 4. *собир.* җитәкчеләр, башлыклар.

**РУКОВО'ДСТВОВАТЬ** *несов. книж. устар.*— к. руководить.

**РУКОВО'ДСТВОВАТЬСЯ** *несов. книж.*— к. руководиться.

**РУКОВОДЯ'ЩИЙ** — 1. җитәкче...; җитәкчелек итүче; *руководящие органы* — җитәкче органнар; 2. *(направляющий)* җитәкче, кулланма булган, юнәлеш бирүче, юнәлткеч, юл күрсәткеч; *руководящая статья* — юнәлеш бирүче мәкалә.

**РУКОДЕ'ЛИЕ** *ср.*— 1. кул эше, кул һөнәре (мәсәлән, чигү, бәйләү); 2. кулдан эшләнгән әйберләр, кул һөнәре әйберләре (чигешләр, бәйләүләр, челтәрләр һ. б. ш.); *выставка рукоделий* — кул һөнәре әйберләре күргәзмәсе.

**РУКОДЕ'ЛЬНИЦА** *ж.*— 1. кул эше (чигү, бәйләү һ. б.) белән шөгыльләнүче; 2. кул эшенә оста, кул эше остасы.

**РУКОДЕ'ЛЬНИЧАТЬ** *несов.*— кул эше эшләү, кул һөнәре белән шөгыльләнү (чигү, бәйләү һ. б. ш.).

**РУКОДЕ'ЛЬНЫЙ** — 1. кул эшләре...-ы; кул һөнәре...-ы; *рукодельный кружок* — кул эшләре түгәрәге; 2. кулдан эшләнгән; *рукодельная скатерть* — кулдан эшләнгән ашъяулык.

**РУКОКРЫ'ЛЫЕ** *мн. зоол.*— кулканатлылар (яркапатлар) семьялыгы.

**РУКОМО'ЙНИК** *м.* — юынгыч (юыну өчен комган кебегрәк асылмалы савыт).

**РУКОПА'ШНАЯ** *в знач. сущ.*— к. рукопашный.

**РУКОПА'ШНЫЙ: рукопашная драка** — кул сугышы, кара-каршы сугышу, кара-каршы килеп сугышу, йодрык сугышы, якыннан торып сугышу; **рукопашный бой** — якыннан торып сугышу, штыкка штык килеп сугышу.

**РУКОПИСА'НИЕ** *ср. книж. устар.*— к. рукопись 1, 2.

**РУКОПИ'СНЫЙ** — 1. кулъязмалар...-ы; *рукописный отдел музея* — музейның кулъязмалар бүлеге; 2. кулъязма..., кулдан язылган, язма (басма түгел); *рукописный текст* — язма текст; *старинные рукописные книги* — борынгы кулъязма китаплар.

**РУ'КОПИСЬ** *ж.*— 1. *редко* язу, кулдан язу; 2. кулъязма (кулдан язылган китап, әсәр яки документ); *отдел рукописей* — кулъязмалар бүлеге; 3. *тип.* кулъязма, кулъязманың төп нөсхәсе (авторның кулдан язып яисә машинкада бастырып, матбугатта чыгару өчен редакциягә яки типографиягә тапшырган язмасы).

**РУКОПЛЕСКА'НИЕ** *ср.*— 1. к. рукоплескать; 2. *чаще мн.* кул чабулар, алкышлаулар; алкышлау тавышлары.

**РУКОПЛЕСКА'ТЬ** *несов. книж.*— кул чабу, алкышлау, алкышлап кул чабу.

**РУКОПОЖА'ТИЕ** *ср. книж.*— кул кысышу, кул бирешү; (кул биреп) күрешү, исәнләшү.

**РУКОПОЛАГА'ТЬ** *несов. церк.*— к. рукоположить.

**РУКОПОЛОЖЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *церк.*— к. рукоположить; *обряд рукоположения* — изге дәрәҗәгә күтәрү йоласы.

**РУКОПОЛОЖИ'ТЬ** *сов. церк.*— изге дәрәҗә бирү, изге дәрәҗәгә күтәрү.

**РУКОПРИКЛА'ДСТВО** *ср. мн.* нет — 1. *офиц. истор.* имза, тамга; имза (кул) кую, тамга салу (элек); 2. *разг. ирон.* кул озайту, кыйнау, сугу.

**РУКОСУ'Й** *м. простореч. бран.*— җобалгы, ачык авыз (җебегән, пешмәгән кеше).

**РУКОТВО'РНЫЙ** *книж. устар.*— кеше хезмәте белән тудырылган (барлыкка китерелгән); кеше кулы тудырган (төзегән).

**РУКОЯ'ТКА** *ж.*— 1. сап; *рукоятка кинжала* — хәнҗәр сабы; 2. *спец. тех.* тоткыч, тотка; 3 чабагач күбәге.

**РУКОЯ'ТЬ** *ж. книж.*— к. рукоятка 1.

**РУЛА'ДА** *ж. муз.*— рулада (җырлаганда тавышны бик тиз үзгәртү; көйнең тиз җырлана торган өлеше, музыкаль бизәк).

**РУЛЕВО'Й** — 1. руль...-ы; *рулевое колесо* — руль тәгәрмәче; 2. койрык...-ы; *рулевые перья у птиц* — кошларда койрык каурыйлары (руль хезмәтен үти торган каурыйлар); 3. *в знач. сущ. м. мор.* рулевой, койрыкчы, койрык тотучы, руль тотучы; койрыкта утыручы, рульне идарә итүче.

**РУЛЕ'НИЕ** I *ср. мн.* нет, *спец.*— к. рулить I.

**РУЛЕ'НИЕ** II *ср. мн.* нет, *ав.*— к. рулить II.

**РУЛЕ'Т** *м. кулин.*— рулет (1. тапаган иттән катлап пешерелгән озынча түгәрәк ашамлык, ит катламасы; 2. эченә вареньe яки башка шундый татлы әйбер салып хәзерләнгән озынча түгәрәк катлама; 3. сөяге алынган дуңгыз боты ите).

**РУЛЕ'ТКА** *ж.*— рулетка (1. үлчәү тасмасы; 2. отышлы уен һәм шуның җайланмасы).

**РУЛИ'ТЬ** I *несов. спец.*— рульне бору, койрыкны бору, койрык тоту.

**РУЛИ'ТЬ** II *несов. ав.*— 1. *(о лётчике)* самолётны җирдән алып бару; 2. *(о самолёте)* җирдән бару, җирдән тәгәрәп (шуып) бару.

**РУЛО'** *ср. нескл.* и **РУЛО'Н** *м. спец.*— рулон, төргәк (мәсәлән, кәгазь, обой һ. б. ш. төргәкләр).

**РУЛЬ** *м.*— 1. *(у автомобиля, самолёта)* руль; 2. *(у лодки, судна)* койрык, руль. 3. *перен. книж.* руль, идарә, җитәкчелек, җитәкче үзәк, башкару руле. ◇ **Без руля и без ветрил** *ирон. перен.*— билгеле бер юнәлешсез, җил искән якка, максатсыз, агым буенча (бару).

**РУМБ** *м. мор.*— румб (компас түгәрәгенең утыз икедән бер өлеше); *четыре румба влево!* — дүрт румб (45°) сулга! (корабльне бору турында команда).

**РУ'МБА** *ж.*— румба (бию төре).

**РУ'МПЕЛЬ** *м. мор.*— румпель, руль рычагы (корабльдә).

**РУМЫ'НКА** *ж.*— 1. румын хатын-кызы; 2. *разг. устар.* румынка, румын ботинкасы (хатын-кызлар өчен төймәле ботинка).

**РУМЫ'НСКИЙ** — румын(нар)...-ы; Румыния...-ы; *румынский язык* — румын теле; *румынская промышленность* — Румыния промышленносте.

**РУМЫ'НЫ** *мн.*— румыннар, румын халкы.

**РУМЯ'НА** *только мн.*— иннек, кызыл (бизәнү өчен кызыл буяу); *натереть щёки румянами* — биткә кызыл сөртү, иннек сөртү.

**РУМЯ'НЕЦ** *м.*— 1. бит кызыллыгы, бит алсулыгы; 2. *перен.* (оялудан һ. б.) бит кызару, биткә кызыллык йөгерү.

**РУМЯ'НИТЬ** *несов.*— 1. кызарту, кызыландыру, алсуландыру; *мороз румянит щёки* — суык битләрне кызарта; 2. кызыл сөртү, иннек сөртү, иннек ягу; 3. *перен.* күкне кызарту (таң яки шәфәкъ).

**РУМЯ'НИТЬСЯ** *несов.*— 1. кызару, кызарыну, кызарып китү, кып-кызыл булу; 2. кызыл сөртү, иннек сөртенү, иннек ягыну, бизәнү; 3. кызарып пешү, кызару, йөзе килү; *пирог начинает румяниться* — пирогның йөзе килә (кызара) башлаган.

**РУМЯ'НКА** *ж. бот.*— сыер теле (үсемлек).

**РУМЯ'НОСТЬ** *ж. мн.* нет — кызыллык, алсулык, кызыл (алсу) булу.

**РУМЯ'НЫЙ — 1.** *(покрытый румянцем)* алсу йөзле, кызыл битле, кызарган йөзле; **2.** *(алый, красный)* ал, кызыл, алсу-кызыл. ◇ **В румяном разливе огня** — кызгылт үт яктысында (ут шәүләсендә).

**РУНДУ'К** *м.*— лар (капкачлы зур әрҗә).

**РУНДУ'ЧНЫЙ** — лар...-ы; *рундучная крышка — лар* капкачы.

**РУНЕ'Ц** *м. зоол.*— йонкояр (бөҗәк).

**РУНИ'СТЫЙ** *устар.*— куе йонлы, йонга бай; йон күп бирә торган; *рунистая порода овец* — куе йонлы сарык токымы.

**РУНИ'ЧЕСКИЙ** *филол.*— руник, рун...-ы; *руническое письмо* — руник язмалар, рун язмалары.

**РУ'ННЫЙ: рунный ход рыбы** — балыкның өер-өер булып йөрүе (мәсәлән, уылдык чәчкәндә).

**РУНО'** I *ср.*— **1.** *книж. поэт.* сарык йоны; **2.** бер сарыктан кыркылган йон.

**РУНО'** II *ср. обл. спец.*— балык өере, балык көтүе.

**РУ'НЫ** *мн. филол.*— **1.** рун язмалары (борынгы скандинавларның таш язмаларда һ. б. әйберләрдә сакланган язулары); **2.** руннар (Карелия халкының һәм финнарның борынгы халык җырлары).

**РУ'ПИЯ** *ж.*— рупия (Һиндстанда бездәге 1 сум 25 тиенгә тиң акча берәмлеге).

**РУ'ПОР** *м.*— **1.** рупор, быргы, тавыш яңгыраткыч (тавыш көчәйткеч труба); *кричать, сложив руки рупором* — кулларны быргы кебек куеп кычкыру; **2.** *перен. книж.* фикер таратучы, идея үткәрүче; ...җырын җырлаучы, ...сүзен сөйләүче; *газета — рупор общественного мнения* — газета ул җәмәгатьчелек фикерен таратучы.

**РУСА'К** I *м. простореч. фам.*— чын рус, рус кешесе (чын рус табигатьле бик гади кеше).

**РУСА'К** II *м.*— үр куяны, соры куян.

**РУСА'ЛИИ** *ед.* нет, *истор.*— русалии (борынгы славяннарда үлгән кешеләр истәлегенә оештырыла торган бәйрәм).

**РУСА'ЛКА** *ж. миф.*— су кызы, су анасы, су сылуы.

**РУСА'ЛОЧИЙ** — су кыз(лар)ы...-ы; су сылулары...-ы; *русалочьи пляски* — су кызлары биюе (су сылулары биюе). ◇ **Русалочий взгляд** — сокландыргыч караш (үзенә тарта торган салкын караш). **Русалочьи глаза** — яшькелт (сокландыргыч, үзенә тарта торган) күзләр.

**РУСА'ЧИЙ** *охот.*— үр куяны...-ы; *русачья шкура* — үр куяны тиресе.

**РУСАЧИ'НА** *м. охот. увелич.*— зур үр куяны.

**РУСА'ЧКА** *ж. разг. шутл.*— к. русак I.

**РУСА'ЧНИК** *м. охот.*— (эт белән куып) үр куяннары аулаучы, үр куяннары ауларга яратучы.

**РУСЕ'ТЬ** *несов. разг.*— коңгырт төскә керү; чәч-төк саргаю.

**РУСИ'ЗМ** *м. лингв.*— русизм (**1.** рус теленнән кергән сүз яки тәгъбир; **2.** рус теле йогынтысында туган тел үзенчәлекләре).

**РУСИ'Н** *м.*, **РУСИ'НКА** *ж.* — к. русины.

**РУСИ'НЫ** *мн.*— русиннар, Карпат украиннары (элекке Румыниянең Галиция өлкәсендә яшәүчеләр).

**РУСИ'СТ** *м. филол.*— русист, рус филологиясе белгече (рус теле һәм әдәбияты галиме).

**РУСИФИКА'ТОР** *м. книж. полит.*— русификатор, руслаштыручы, руслаштыру политикасын үткәрүче, руслаштыру тарафдары (патша Россиясендә).

**РУСИФИКА'ТОРСКИЙ** *книж. полит.*— көчләп руслаштыру...-ы; русификаторлык ...-ы; *русификаторская политика царского правительства* — патша хөкүмәтенең русификаторлык политикасы, көчләп руслаштыру политикасы.

**РУСИФИКА'ТОРСТВО** *ср. мн.* нет, *книж. полит.*— русификаторлык, руслаштыру политикасы.

**РУСИФИКА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *книж. полит.*— русификация, көчләп руслаштыру (патша Россиясендә рус булмаган халыкларны көчләп руслаштыруга тырышудан гыйбарәт булган политика).

**РУСИФИЦИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж. полит.*— руслаштыру, көчләп руслаштыру, русификация үткәрү.

**РУСИФИЦИ'РОВАТЬСЯ — 1.** *сов.* и *несов.* — руслашу, руслаша бару; **2.** *несов. страд.* руслаштырылу, көчләп руслаштырылу; русификация үткәрелү.

**РУ'СЛО** *ср.*— **1.** *геогр.* елга юлы (елганың су ага торган төп юлы); **2.** *перен.* юл, эз, юнәлеш; рәвеш, калып; *жизнь пошла по новому руслу* — тормыш яңа эздән китте, яңа эз алды; *жизнь вошла в своё нормальное русло* — тормыш яңадан үзенең элекке эзенә төште (элекке хәленә кайтты).

**РУСЛООЧИСТИ'ТЕЛЬНЫЙ** *тех.*— елганы чистарта торган; елга юлын чистарту ...-ы; *руслоочистительные машины* — елга юлын чистарту машиналары.

**РУСОБОРО'ДЫЙ** — аксыл-сары сакаллы.

**РУСОВОЛО'СЫЙ** — аксыл-сары чәчле.

**РУСОГОЛО'ВЫЙ** — к. русоволосый.

**РУСОКО'СЫЙ** — аксыл-сары толымлы.

**РУСОКУ'ДРЫЙ** — аксыл-сары бөдрә чәчле.

**РУСС** *м. устар. поэт. торж.*— к. росс.

**РУ'ССКАЯ** I *ж.*— рус халык биюе.

**РУ'ССКАЯ** II *ж.*— рус хатыны, рус кызы; рус хатын-кызы.

**РУ'ССКИЕ** *мн.*— руслар, рус халкы, рус милләте.

**РУ'ССКИЙ** I *м.*— рус, рус кешесе.

**РУ'ССКИЙ** II — **1.** рус...-ы; *великий русский народ* — бөек рус халкы; **2.** Россия ...-ы; Русь...-ы; *русская история* — Россия тарихы. ◇ **Русским языком (сказать, говорить)** *разг. перен.*— ачык итеп, аңлашылырлык итеп, аңлаешлы телдә (әйтү, сөйләү).

**РУССОИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *истор.*— руссоизм, руссочылык (18 гасырда яшәгән француз галиме Ж.-Ж. Руссоның социаль һәм

педагогик тәгълиматына нигезләнгән карашлар системасы).

**РУССОИ'СТ** *м. истор.*— руссочы, руссоизм яклы (руссоизм тарафдары яки аны дәвам иттерүче).

**РУССОФИ'Л** *м. книж. истор.*— руссофил, рус дусты (рус халкын, телен, гореф-гадәтләрен яратучы; Россия белән якынлашу политикасын яклаучы).

**РУССОФО'Б** *м. книж. устар.*— руссофоб, рус дошманы (Россия һәм рус халкы белән якынлашуга, дуслашуга каршы политика үткәрүче).

**РУСТ** *м. архит.*— руст (биналарны рустика алымы белән бизәүдә кулланыла торган, шомартылмаган кытыршы таш).

**РУ'СТИКА** *ж. архит.*— рустика (архитектурада бинаның тышкы ягын шомартылмаган кытыршы таш белән бизәкләү алымы).

**РУСТОВА'ТЬ** *несов. архит.*— рустлау, (бинаны) кытыршы таш белән тышлау, рустлар белән бизәү.

**РУСТО'ВКА** *ж. архит. мн.* нет — к. рустовать.

**РУСЬ** *ж. истор.*— Русь.

**РУ'СЫЙ** — аксыл-сары, коңгырт-сары; аксыл-сары чәчле, саргылт чәчле; *русый парень* — аксыл-сары чәчле егет.

**РУ'ТА** *ж. бот.*— рута, сәдәп уты (көньякта үсә торган сары чәчәкле, яфрагыннан эфир мае алына торган куак үсемлек).

**РУТЕ'** *ср. нескл.*— ота торган карта, бәхетле карта. ◇ **Играть на руте** — һаман бер картага уйнау (отышлы уенда).

**РУТЕ'НИЕВЫЙ** *хим.*— рутений...; рутенийдан ясалган; *рутениевый волосок* — рутенийдан ясалган бик нечкә металл чыбык.

**РУТЕ'НИЙ** *м. мн.* нет, *хим.*— рутений (химик элемент; авыр эрүчән металл).

**РУТЕ'Р** *м. спец.*— рутер, рутер машинасы (ташлы каты җирләрне йомшарту өчен кулланыла торган корыч тешле җирказыгыч машина).

**РУТЁРКА** *ж. разг. устар.*— к. руте.

**РУТИ'НА** *ж. книж. неодобр.*— искелек, искелеккә сукырларча буйсыну, консервативлык, торгынлык, катып калганлык.

**РУТИНЁР** *м. книж. неодобр.*— рутинёр торгынлыкны (искелекне) яклаучы (иске шаблон буенча эш итүче, иске гореф-гадәтләргә ябышып ятучы, искелеккә сукырларча буйсынучы).

**РУТИНЁРСКИЙ** *книж. неодобр.*— рутинёрлык...-ы; рутинёрларча...; катып калган, иске; *рутинёрские взгляды* — иске карашлар.

**РУТИНЁРСТВО** *ср. мн.* нет, *книж. неодобр.*— искелек, рутинёрлык, торгынлык, катып калганлык, консервативлык.

**РУТИ'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж. неодобр.*— артка калган (искергән, катып калган) булу, торгынлыкта булу.

**РУТИ'ННЫЙ** *книж. неодобр.*— искереп беткән, катып калган, торгын; әллә кайчаннан калган; консерватив; *рутинная техника* — искереп беткән техника; *рутинное отношение к делу* — эшкә консерватив мөнәсәбәт.

**РУ'ТОВЫЙ** *бот. тех.*— рута...-ы; рута үләненнән алынган; *рутовое масло* — рута мае.

**РУ'ХЛЯДЬ** *ж. мн.* нет, *собир. разг.*— иске-москы, артык-портык, алам-салам, вак-төяк йорт әйберләре.

**РУХЛЯ'К** *м. геол.*— йомшак токым, мергель.

**РУ'ХНУТЬ** *сов.*— **1.** ишелү, аву; гөрселдәп җимерелеп төшү, ишелеп (авып) төшү, ватылып төшү; *мост рухнул* — күпер ишелеп төште; *стена рухнула* — стена җимерелеп төште; **2.** *перен.* җимерелү, таркалу; юкка чыгу, җилгә очу; (эш) бозылу, барып чыкмау; *рухнули надежды* — өметләр юкка чыкты; *планы врагов рухнули* — дошманнарның планнары җимерелде.

**РУ'ХНУТЬСЯ** *сов. разг.*— к. рухнуть.

**РУЧА'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет — ышандыру, гарантия.

**РУЧА'ТЬСЯ** *несов.* — ышану, ышан(дыр)ып әйтү, кистереп (өзеп) әйтү, гарантия бирү; (җаваплылыкны) өстенә алу; *ручаться за качество товара* — товарның сыйфаты яхшы булуына гарантия бирү; *я готов ручаться за него головой* — мин аның өчен башымны кистерергә әзер (ягъни мин аңа бик нык ышанам).

**РУЧЕЁК, РУЧЕ'Й** *м.*— **1.** инеш, кечкенә елга, чишмә; *горный ручей* — тау инеше; **2.** гөрләвек, ташу суы. ◇ **Кровь лилась ручьём** — кан елга булып акты.

**РУЧЕЙ'НЫЙ** — инеш...-ы; *ручейное русло* — инеш үзәге, инеш юлы.

**РУЧИ'ЩА** *ж. разг.*— зур кул, тупас кул.

**РУ'ЧКА** *ж.*— **1.** кул, кечкенә кул; **2.** тотка, тоткыч; бау, сап; култыкса; *дверная ручка* — ишек тоткасы; *ручка кресла* — кресло култыксасы; **3.** колак; *ручка самовара* — самовар колагы; **4.** каләм сабы, ручка; *автоматическая ручка* — автомат ручка. ◇ **До ручки дойти (довести)** *простореч. фам. перен.*— иң соңгы чиккә җит(кер)ү, аптыратып-йөдәтеп бетерү, аптырау, бик нык рух төшү. **Под ручку (взять, ходить)** *разг.*— култыклау, култыклап алу; култыклашып йөрү. **К ручке подойти** *(устар.)* — кул үбү, кул үбәргә килү.

**РУЧНИ'К** I *м.*— **1.** *спец.* (берәр эшне) кулдан башкаручы эшче, кулдан эшләүче оста; *ручник-скорняк* — кулдан эшләүче скорняк; **2.** *плотн.* кечкенә корыч чүкеч.

**РУЧНИ'К** II или **РУШНИ'К** *м. обл.*— кул сөрткеч, сөлге, тастымал.

**РУЧНИ'К** III или **РУШНИ'К** *спец.*— ручник, кыска саплы пумала (малярларда).

**РУЧНИ'СТ** *м. апт.*—дару сатучы (рецептсыз сатыла торган бүлектә эшләүче аптека эшчесе).

**РУЧНИ'ЦА** *ж. спец.* — к. ручник I в 1 знач; *ручница-вышивальщица* — кул белән чигүче.

**РУЧНО'Й** — **1.** кул...-ы; *ручной труд* — кул хезмәте; *ручные часы* — кул сәгате; **2.** кулдан эшләнгән, кул белән...; *ручная*

*работа* — кулдан эшләнгән әйбер; *ручная сигнализация* — кул белән сигнал бирү; 3. кулга өйрәтелгән, иләштерелгән; кулга өйрәнгән, иләшкән; *ручной медведь* — кулга иләшкән аю; 4. *перен. разг. (о человеке)* буйсынучан, тыңлаучан, кулга бирелүчән, күндәм. ◇ **Ручная продажа** *торг.* — 1. йөреп сату, кулдан сату; 2. рецептсыз сату (даруларны). **Ручной язык** *лингв.* — кул (ымлау, ишарә) теле. **Ручной багаж** — кул багажы, җиңел багаж.

**РУЧНЯ'** *ж. обл.* — (бер)уч, учма, тотам.

**РУЧО'НКА** *ж. ласкат.* — кулкай, кулчык (матур, кечкенә кул турында сөеп әйтелә).

**РУЧЬЕВО'Й** — инеш...-ы; гөрләвек...-ы; *ручьевая вода* — инеш суы.

**РУЧЬИ'СТЫЙ** *устар.* — инеш (гөрләвек) булып ага торган.

**РУ'ШЕНИЕ** *ср. мн.* нет, *спец.* — к. рушить II.

**РУШИ'ЛЬНЫЙ** *спец.* — ярма ярдыру (бөртекне кабыгыннан аеру, кабыгын арчу)...-ы; *рушильная машина* — ярма ярдыру машинасы.

**РУ'ШИТЬ** I *несов.* — 1. *(ломая валить)* җимерү, аудару, ишү; егу, түндерү; 2. *перен. устар.* вату, җимерү, бозу, юкка чыгару (мәсәлән, иске гореф-гадәтләрне); 3. *старин.* и *обл.* турау, кисәкләргә бүлгәләү; тураклау, кискәләү (мәсәлән, икмәкне, пешкән тавыкны һ. б.).

**РУ'ШИТЬ** II *несов.* — ярма ярдыру, кабыгыннан аеру, кабыгын куптару (арчу), чистарту; *рушить просо* — тары ярдыру.

**РУ'ШИТЬСЯ** *сов.* и *несов.* — 1. ишелү, аву, җимерелү; җимерелеп (ишелеп, авып) төшү; ватылып (таркалып) бетү; *здание рушится* — бина ишелә (җимерелә); 2. *перен.* җимерелү, бозылу; юкка чыгу, җилгә очу; эшкә (гамәлгә) ашмау, челпәрәмә килү; *надежды рушились* — өметләр җилгә очты; *всё вдруг рушилось* — кинәт барысы да җимерелде (юкка чыкты).

**РУШНИ'К** *м. обл.* — к. ручник II, III.

**РЦЫ** *ср. нескл. устар.* — „р" хәрефенең исеме.

**РЫ'БА** *ж.* — 1. балык; *морская рыба* — диңгез балыгы; *речная рыба* — елга балыгы; 2. *кулин.* балык ите (кыздырган яки пешергән балык); 3. *перен. разг. пренебр. (о человеке)* сүлпән кеше, салкын канлы (дәртсез) кеше; җебегән, бозау. ◇ **В мутной воде рыбу ловить** — к. ловить. **Как рыба в воде** — к. вода. **Ни рыба, ни мясо** *разг. пренебр. перен.* — хайван дисәң йоны юк, адәм дисәң коны (юне) юк. **Биться, как рыба об лёд** — к. биться. **Белая рыба** *собир. спец.* — ак балык (кылчыклы түбән сорт балыклар). **Красная рыба** *собир. спец.* — кызыл балык (кылчыксыз югары сорт балыклар, мәсәлән, чөгә). **Рыба-тарашка** *зоол.* — тарак балык. **Мелкая рыба** — вак балык, маймыч.

**РЫБА'К** *м.* — балыкчы, балык тотучы; *(неводом.)* балык сөзүче; *(удочкой)* кармак салучы.

**РЫБАКОВА'ТЬ** *несов. обл.* — к. рыбачить.

**РЫБА'ЛКА** *обл.* — 1. *ж.* балык тоту, балык сөзү; кармак салу, балык каптыру; 2. *м.* и *ж.* к. рыбак, рыбачка 1.

**РЫБА'РЬ** *м. устар.* — к. рыбак.

**РЫБА'ЦКИЙ** — балыкчылык (балык тоту)...-ы; балыкчылар...-ы; *рыбацкий колхоз* — балыкчылык колхозы; *рыбацкая кооперация* — балыкчылар кооперациясе.

**РЫБА'ЧИЙ** — 1. балыкчы...-ы; *рыбачья хата* — балыкчы өе; 2. балык...-ы; балык тота торган; *рыбачьи сети* — балык ятьмәсе, җылым.

**РЫБА'ЧИТЬ** *несов.* — 1. балык тоту, балыкчы булу; балыкчылык белән шөгыльләнү; 2. *(неводом)* балык сөзү; 3. *(удочками)* кармак салу, балык каптыру.

**РЫБА'ЧКА** *ж.* — 1. балыкчы хатын, балыкчы кыз; 2. балыкчы хатыны.

**РЫБЁШКА** *ж.* — 1. *разг. пренебр.* вак балык, вак чабак; 2. *обл.* маймыч, маймa.

**РЫ'БИЙ** — 1. балык...-ы; *рыбья чешуя* — балык тәңкәсе; *рыбий пузырь* — балык куыгы (йөзү куыгы, шартлавык); *рыбий жир* — балык мае; *подавился рыбьей костью* — тамагына балык кылчыгы кадалган; 2. *перен.* балыкныкы төсле, төссез, җансыз, нурсыз, рухсыз; *рыбьи глаза* — (балыкныкы төсле) нурсыз күзләр.

**РЫ'БИНА** *ж. разг.* — бер зур балык; 2. *спорт. спец.* (көймә төбенә салынган) такта.

**РЫ'БИНКА** *ж. разг. уменьш.* — бер кечкенә балык.

**РЫ'БИЩА** *ж. разг.* — зур балык.

**РЫ'БКА** *ж. разг.* — вак балык, кечкенә балык.

**РЫ'БНИК** *м.* — 1. *торг.* балык сатучы, балык белән сәүдә итүче; 2. *спец.* балык хуҗалыгы белгече, балык промыселы эшчесе; 3. *обл.* балык бәлеше, балык пирогы.

**РЫ'БНИЦА** *ж. спец. обл.* — 1. балык тоту судносы; балыкчы көймәсе (каегы); 2. балык амбары (тотылган балык урнаштырыла торган урын).

**РЫ'БНЫЙ** — балык...-ы; балыктан хәзерләнгән (пешерелгән); *рыбные консервы* — балык консервысы; 2. балыклы; балыгы күп, балыкка бай; *рыбное озеро* — балыклы күл; 3. *разг.* балыктан бушаган, балык исе сеңгән (килә торган); *рыбная тарелка* — балыктан бушаган тәлинкә; *рыбные руки* — балык исе сеңгән куллар. ◇ **Рыбная ловля** — балык тоту.

**РЫБОВЕ'ДЕНИЕ** *ср. книж. мн.* нет — балыкчылык белеме.

**РЫБОВО'Д** *м.* — балык үрчетүче, балык үрчетү (балыкчылык) белгече.

**РЫБОВО'ДНЫЙ** *спец.* — балык үрчетү...-ы; балык үрчетә торган; *рыбоводный пруд* — балык үрчетә торган буа; *рыбоводный завод* — балык үрчетү хуҗалыгы (заводы).

**РЫБОВО'ДСТВО** *ср. мн.* нет — балыкчылык; балык үрчетүчелек.

**РЫБОВО'ДЧЕСКИЙ** — балыкчылык (балык үрчетү)...-ы; *рыбоводческое хозяйство* — балык үрчетү хуҗалыгы.

**РЫБОДОБЫ'ЧА** *ж. спец. книж.* — балык тотыш, балык тоту; *план рыбодобычи* —

балык тоту планы; *низкая рыбодобыча* — балык тотыш түбән булу.

**РЫБОЗАВО'Д** *м.*— балык заводы (тотылган балыкны тозлау, консервлау, киптерү, ыслау һ. б. рәвешчә эшкәртү заводы).

**РЫБОКОМБИНА'Т** *м.*— балык комбинаты, балык эшкәртү комбинаты.

**РЫБОКОПТИ'ЛЬНЫЙ** — балык ыслый торган, балык ыслау...-ы; *рыбокоптильное помещение* — балык ыслау бинасы.

**РЫБОКОПТИ'ЛЬНЯ** *ж.*— балык ысла(т)у урыны (бинасы, заводы).

**РЫБОКОПТИ'ЛЬЩИК** *м. спец.*— балык ыслаучы эшче; балык ыслау белгече, остасы.

**РЫБОЛО'В** *м.*— 1. *(рыбак)* балыкчы, балык тотучы; балык сөзүче; кармак салучы, балык каптыручы, кармакчы; 2. *зоол.* акчарлак(ларның бер төре).

**РЫБОЛОВЕ'ЦКИЙ** — балык тота торган, балыкчылык...-ы; балык тоту...-ы; *рыболовецкий колхоз* — балыкчылык колхозы; *рыболовецкое судно* — балык тоту судносы.

**РЫБОЛО'ВНЫЙ** — 1. балык тоту...-ы; балык тоту өчен кирәк булган; балык тота торган; *рыболовные принадлежности* — балык тоту кораллары; 2. балык...-ы; балыкчылык...-ы; *рыболовный промысел* — балык промыселы; *рыболовный район* — балыкчылык районы (балык тоту белән шөгыльләнә торган район).

**РЫБОЛО'ВСТВО** *ср. мн.* нет — балык тоту(чылык); балыкчылык; балыкчылык тармагы (халык хуҗалыгының).

**РЫБОНАСО'С** *м. тех.*— балык бушаткыч, балык насосы (тотылган балыкларны корабльдән коры җиргә бушата торган насос).

**РЫБОПОДЪЁМ** *ж. тех.*— к. рыбоход.

**РЫБОПОДЪЁМНИК** *м. спец.*— балык үткәргеч (буа, плотина аша балык үтү өчен ясалган махсус юллыклар).

**РЫБОПОДЪЁМНЫЙ** *тех.*— балык үткәрә торган, балык үткәрү...-ы; балык үткәргеч...-ы; *рыбоподъёмные сооружения* — балык үткәрү корылмалары.

**РЫБОПРИЁМНЫЙ** *спец.*: **рыбоприёмный пункт** — тотылган балыкны кабул итү пункты.

**РЫБОПРОДУ'КТЫ** *мн.*— балык продуктлары, балык азыклары, балыктан хәзерләнгән азык-төлек.

**РЫБОПРОМЫСЛО'ВЫЙ** *спец.*— балык тоту (балык промыселы) белән шөгыльләнә торган; балыкчылык (балыкчылар)...-ы; *рыбопромысловая артель* — балыкчылык артеле.

**РЫБОПРОМЫ'ШЛЕННИК** *м. дореволю*— балык заводлары (промыселлары) тотучы, балык заводы хуҗасы.

**РЫБОПРОМЫ'ШЛЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — балык промышленносте.

**РЫБОПРОМЫ'ШЛЕННЫЙ** — 1. балык промышленносте...-ы; *рыбопромышленный район* — балык промышленносте районы (балык тоту һәм эшкәртү районы); 2. балык промыселы (балык тоту)...-ы; *рыбопромышленная техника* — балык промыселы техникасы.

**РЫБОРАЗВО'ДНЯ** *ж. спец.*— балык үрчетү урыны, балык буасы.

**РЫБОТОРГО'ВЕЦ** *м. устар.*— балык сатучы, балык белән сәүдә итүче.

**РЫБОТОРГО'ВЛЯ** *ж. мн.* нет — балык сәүдәсе, балык белән сәүдә итү, балык сату.

**РЫБОТОРГО'ВЫЙ** *книж.*— балык сату...-ы; балык белән сәүдә итү...-ы; *рыботорговое заведение* — балык белән сәүдә итү йорты.

**РЫБОХО'Д** *м. тех.*— балык юлы, балык үткәргеч (буаларда, плотиналарда балык үтү өчен ясалган махсус тишекләр).

**РЫБОХО'ДНЫЙ**: **рыбоходное устройство** *спец.*— балык үткәргеч җайланма.

**РЫБОЯ'ДНЫЙ** *спец.*— балык ашаучы, балык ашый торган.

**РЫБОЯ'ЩЕР** *м. зоол.*— к. ихтиозавр.

**РЫБЧО'НКА** *ж. разг. пренебр.*— кечкенә балык, маймыч, маймa.

**РЫВО'К** *м.*— 1. (кинәт) тарту, тартылу, ыргылу; *лошади бросились сильным рывком вперёд* — атлар кинәт тартылып кузгалып киттеләр (алга ыргылдылар); 2. *спорт.* ыргым (штанга һ. б. ш. авырлыкларны кинәт өскә күтәрү); 3. *разг.* тартып селкү, тарткалау, йолыккалау; 4. *перен.* (план үтәүне вакытлыча) көчәйтеп җибәрү.

**РЫГА'ТЬ** *несов.*— кикерү, кикереп чыгару.

**РЫГА'ТЬСЯ** *безл.*— кикертү.

**РЫГНУ'ТЬ** *сов. однокр.*— кикерү, кикереп чыгару, кикереп кую.

**РЫГОТА'** *ж. мн.* нет, *простореч.*— кикерү, кикерек.

**РЫДА'ЛЕЦ** *м. ирон.*— зар елаучы, күз яше түгүче, сыкранучы, шыншучы.

**РЫДА'ЛЬЩИЦА** *ж. обл.*— елаучы, сыктаучы.

**РЫДА'НИЕ** *ср.*— к. рыдать.

**РЫДА'ТЬ** *несов.*— елау, кычкырып (акырып) елау, зар елау, иңрәп елау; өзәләнә-өзәләнә елау, үксеп-үксеп елау, үкереп елау.

**РЫДВА'Н** *м.*— 1. *старин.* рыдван (зур карета); 2. начар зур арба; көлтә арбасы.

**РЫЖЕБОРО'ДЫЙ** — җирән сакаллы, кызгылт-сары сакаллы.

**РЫЖЕВА'ТЫЙ** — җирәнсу, җирәнсымаграк, кызгылт-сары.

**РЫЖЕВОЛО'СЫЙ** — җирән чәчле, кызгылт-сары чәчле.

**РЫЖЕ'Й** *м. бот.* — к. рыжик 2.

**РЫЖЕ'ТЬ** *несов.*— җирәнләнү, җирәнәю; кызгылт-сары төскә керү.

**РЫЖЕЧА'ЛЫЙ** *спец.*— бурлы җирән, кызыл бурлы (ат төсе).

**РЫЖЕШЁРСТЫЙ** — җирән йонлы, кызгылт-соры йонлы, җирән.

**РЫ'ЖИЙ** — 1. җирән, җирән төсле; кызгылт-сары; кызгылт йонлы; җирән чәчле; *конь рыжей масти* — җирән ат; *рыжий человек* — җирән чәчле кеше; 2. *(выцветший)* уңып саргаеп беткән; 3. *разг. в знач.*

*сущ. м.* сәвәләй, жирәнбаш (цирк клоуны турында әйтелә).

**РЫ'ЖИК** I *м.*— 1. *бот. (гриб)* сары гөмбә, нарат гөмбәсе; 2. *(трава)* шепкән; 3. *разг. фам.* жирәнкәй (жирән чәчле бала; жирән колын һ. б. турында).

**РЫ'ЖИК** II *м. разг. фам.*— Рыжик, Сарбай (кызгылт-сары йонлы эт яки песинең кушаматы).

**РЫ'ЖИКОВЫЙ** *спец.*— 1. сары гөмбә (нарат гөмбәсе)...-ы; *рыжиковый суп* — нарат гөмбәсе ашы; 2. шепкән...-ы; *рыжиковое масло* — шепкән мае.

**РЫК** *м.*— 1. к. рыкать; 2. үкергән тавыш, үкерү; *львиный рык* — арслан үкерүе.

**РЫКА'ТЬ** *несов.*— ачы итеп үкерү, кыргый тавыш белән акыру, бакыру, ырлау; дәһшәтле акыру.

**РЫЛЕ'ЙКА** *ж. обл.*— к. рыля.

**РЫ'ЛО** *ср.*—1. *(морда животных)* борын, танау; 2. *вульг. (о человеке)* шыксыз бит. ◇ **Рылом не вышел** *простореч. фам.* — 1. ямьсез, шыксыз; 2. *перен.* берничә ярарлык түгел, туры килми. **Ни уха, ни рыла (не смыслить)** *вульг.*— берни аңламау, ике бозауга кибәк тә аерып бирә белмәү.

**РЫЛОВОРО'Т** *м. вульг.*— ямьсез (иләмсез, килбәтсез) кеше, котсыз кеше.

**РЫ'ЛЬЦЕ** *ср.*— 1. к. рыло; *лисье рыльце* — төлке танавы; 2. *бот.* авызчык (чәчәкнең аналык өлешендә). ◇ **Рыльце в пуху (в пушку)** у кого — к. пух. **Рыльце чайника** *обл.*— чәйнек борыны.

**РЫ'ЛЯ** *ж. обл.*— к. лира I во 2 знач.

**РЫМ** *м. мор.*— боҗра, причал боҗрасы (корабльләр туктый торган урыннарда причал арканын бәйләү өчен ярга беркетелгән зур тимер боҗра).

**РЫ'НДА** I *м. истор.*— сарай сакчысы, ян сакчысы, тән сакчысы (элекке Мәскәү патшаларының сараенда).

**РЫ'НДА** II *ж. спец. мор.*: **рынду бить** — төш җиткәнен белгертеп чаң кагу.

**РЫ'НОК** *м. (мн.* рынки*)* — 1. базар; *колхозный рынок* — колхоз базары; 2. *экон.* базар; *рынки сбыта* — товар чыгару базарлары; *внешний рынок* — тышкы базар (чит илләргә товар чыгару); 3. *перен. простореч. пренебр. (галдёж, спор)* базар, кычкырыш, шау-шу, чыр-чу, тавыш-гауга; бәхәс.

**РЫ'НОЧНЫЙ** — 1. базар...-ы; базардагы; *рыночная цена* — базар(дагы) бәясе; 2. *разг. устар. (грубый, небрежный)* базарлык, базар өчен (сату өчен) эшләнгән; тупас, алама, начар (эш), аннан-моннан гына (миннән киткәнче, иясенә җиткәнче дип) эшләнгән.

**РЫП** *м. обл.*: **сапоги с рыпом** — шыгырдавыклы итек.

**РЫ'ПАТЬ, РЫПЕ'ТЬ** *несов. обл.*— шыгырдау.

**РЫ'ПАТЬСЯ** *несов. простореч. фам.*— берәр нәрсә эшләргә тыпырчыну, чәбәләнү, җилкенү, талпыну; тыкшыну, катышу; *сиди и не рыпайся* — тик кенә утырып тор, тыпырчынма.

**РЫСА'К** *м.*— юртак.

**РЫСЁНОК** *м. (мн.* рысята*)* — селәүсен баласы (к. рысь II).

**РЫ'СИЙ** — 1. селәүсен...-ы; рысь...; селәүсен тиресеннән тегелгән; *рысий мех* — селәүсен меха; *рысий воротник* — рысь яка; 2. *перен. (о глазах)* селәүсен (күз); уйнак, йөгерек, сизгер, үткер, очлы (күз).

**РЫСИ'СТОСТЬ** *ж. мн.* нет — юртаклык, юртак булу.

**РЫСИ'СТЫЙ** — юртак, яхшы юырта торган, юыртып чаба торган; *рысистая лошадь* — яхшы юырта торган ат.

**РЫСИ'ТЬ** *несов. спорт.* — юыртып бару, юыртып чабу.

**РЫСИ'ХА** *ж.*— ана (әнкә) селәүсен.

**РЫСК** *м. мн.* нет, *спец.*— к. рыскать I, II.

**РЫ'СКАТЬ** *несов.*— 1. эзләнеп йөрү; әрле-бирле иснәнеп йөрү, әрле-бирле чабып йөрү; *степью рыщут волки* — далада бүреләр эзләнеп йөриләр; *гончие рыскают* — ау этләре әрле-бирле иснәнеп йөриләр; 2. *простореч. фам. (искать)* актару, актарыну, эзләнү; *рыскать по карманам* — кесә актару. ◇ **Рыскать по свету** *неодобр.*— сукбайланып йөрү, каңгырып йөрү (яки илдән илгә йөрү).

**РЫ'СКАТЬ** II *несов. мор.*— 1. *(о парусном судне)* җилгә каршы борылу (әйләнү); 2. көймәдә агым уңаена йөзү, фарватердан чыкмас өчен төрле алымнар кулланып йөзү (җилкән күтәрү-төшерү, колга белән этү, якорь салу һ. б.).

**РЫСКЛИ'ВЫЙ** — 1. *охот. (о собаке)* елдам, житез, йөгерек; 2. *мор. (о парусном судне)* җилгә каршы борылучан.

**РЫ'СКНУТЬ** *сов. однокр. мор.*— (көймә) җилгә каршы борылып китү, әйләнеп кую.

**РЫСКОВО'Й**: **рысковой якорь** *мор.*— манёврлау якоре (көймәне борганда турылау өчен кулланыла).

**РЫСЦА'** *ж. мн.* нет — җиңелчә юырту, вак-вак кына юырту, тырык-тырык юырту.

**РЫСЬ** I *ж.*— 1. *(аллюр)* юырту, юыртып чабу; 2. *перен. разг. шутл. (прыть)* житезлек, елгырлык, өлгерлек.

**РЫСЬ** II *ж.*— селәүсен, рысь (мәчесыман ерткыч хайван).

**РЫ'СЬЮ** *нареч.*— 1. *(о лошади)* юыртып, юырттырып; 2. *перен. разг. шутл. (о человеке)* йөгереп, чабып, очып, ашыгыч, тиз. ◇ **Плестись рысью** — әкрен генә юырту (ат турында).

**РЫ'ТВИНА** *ж.*— тәгәрмәч чокыры, чокыр-чакыр, казылма, сикәлтә.

**РЫ'ТЫЙ** — казылган, чокылган, ергаланган; казылмалы, чокыр-чакырлы, канаулы. ◇ **Рытый бархат** *истор. нар.-поэт.*—яхшы сыйфатлы (нәфис, йомшак) бәрхет, хәтфә.

**РЫТЬ** *несов.*— 1. казу, чоку; еру; ерып бару; *рыть канаву* — канау казу; *крот роет ход* — сукыр тычкан үзенә юл ерып бара; 2. *разг. (раскидывать в беспорядке)* актару, таратып (чәчеп, туздырып) ташлау; актарыну, казыну, чокчыну (әйберләр арасында). ◇ **Конь роет копытом землю** — ат ярсып (тибенеп) тора. **Землю рыть**

*разг. фам.*— 1. атлыгып (ашкынып) тору; тырышып эшләү; 2. җир актару, актарып чыгару (зур эш, уңыш казанган кеше турында).

**РЫ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. казыну, җир казу, казып маташу; *свинья роется в земле* — дуңгыз җирдә казына; 2. *перен.* казыну, актарыну, эзләну, чокчыну, кармалау; *рыться в старых журналах* — иске журналларда актарыну (актаргалап утыру); *рыться в карманах* — кесәләрне кармалап карау(чыгу); *рыться в архивах* — архивта казыну; 3. *страд.* казылу, актарылу, актарып ташланылу. ◇ **Рыться в своих воспоминаниях** — үзеннең башыннан кичергәннәрне (үткәннәрне) искә төшерү.

**РЫХЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *с.-х.*— к. рыхлить.

**РЫХЛЕ'ТЬ** *несов.*— 1. йомша(р)у, йомшаклану; көпшәкләнү, күперү, мамык кебек булу (мәсәлән, җир, туфрак); 2. *перен. простореч.* (тән) көпшәкләнү, юанаю, артык ит үсү, ит басу.

**РЫХЛИ'ТЕЛЬ** *м. с.-х.*— (җир, туфрак) йомшарткыч.

**РЫХЛИ'ТЬ** *несов.*— (җирне) йомшарту, мамык кебек итү; *рыхлить междурядья* — рәт араларын йомшарту.

**РЫ'ХЛОСТЬ** *ж. мн.* нет — йомшаклык, уалучанлык, таралучанлык; артык симезлек (буш тәнлелек).

**РЫ'ХЛЫЙ** — 1. *спец.* йомшак, йомшартылган, күпереп торган; *рыхлая земля* — йомшак җир, күпереп торган җир; 2. көпшәк, тишекле-тошыклы; ватылучан, уалучан, таралып китүчән; *рыхлый камень* — көпшәк таш; *рыхлое дерево* — көпшәк агач (муртайган); 3. *перен. простореч. (тучный, дряблый)* көпшәк тәнле, буш тәнле (юан симез кеше турында). ◇ **Рыхлые миндалины** *мед.*— (хроник ангина авыруыннан) йомшарган тамак бизләре.

**РЫХЛЯ'К** *м.*— 1. кимек таш, көпшәк таш (уалып тора торган йомшак тау токымнары); 2. *перен. простореч. (о человеке)* зәгыйфь (хәлсез) кеше, какшаган (ватылган) кеше.

**РЫ'ЦАРСКИЙ** — 1. рыцарьлык...-ы; рыцарь(лар)...-ы; *рыцарские времена* — рыцарьлык заманнары; *рыцарские доспехи* — рыцарьларның тимер киемнәре; 2. *книж. перен.* рыцарьларча, каһарманнарча, галиҗанәпләрчә; *рыцарское отношение к женщинам* —хатын-кызларга карата рыцарьларча мөнәсәбәттә булу, хатын-кызлар белән рыцарьларча мөгамәлә итү. ◇ **Рыцарские романы** *лит.*— рыцарь романнары (Урта гасыр Көнбатыш әдәбиятында рыцарьларның гаҗәеп маҗараларын тасвирлаган әдәби әсәрләр).

**РЫ'ЦАРСТВО** *ср. мн.* нет — 1. *истор.* рыцарьлык, рыцарьлар катлавы, рыцарьлар сословиесе; рыцарьлар; *французское рыцарство* —француз рыцарьлары; 2. рыцарьлык дәрәҗәсе, рыцарьлык исеме; *получить рыцарство* — рыцарьлык дәрәҗәсе алу; 3. *перен. книж.* фидакарьлек, киң күнеллелек, галиҗанәплек; *проявить рыцарство* — фидакарьлек күрсәтү.

**РЫ'ЦАРСТВОВАТЬ** *несов. устар.* — рыцарь булу, рыцарьларча яшәү; рыцарьлык күрсәтү, рыцарьларча эш итү, ирлек (олы җанлылык) күрсәтү.

**РЫ'ЦАРЬ** *м.* — 1. *истор.* рыцарь (Көнбатыш Европада феодализм дәверендә атлы гаскәрдә хезмәт иткән хәрби дворян катлавы вәкиле); 2. *перен. книж.* фидакарь хезмәт итүче, батыр ир, каһарман, рыцарь; *Дзержинский—рыцарь революции* — Дзержинский революция каһарманы ул. ◇ **Рыцарь без страха и упрёка** *книж. перен.*— куркусыз кеше, каһарман; тапсыз намуслы кеше. **Рыцарь печального образа** — аянычлы образ рыцаре (к. Донкихот). **Рыцари большой дороги** *ирон.* — олы юл каһарманнары (талаучылар, юлбасарлар турында). **Рыцари труда** *истор.* — хезмәт каһарманнары (кайбер илләрдә революцион профсоюзларның атамасы).

**РЫЧА'Г** *м.* — 1. *физ. тех.* рычаг (әйбер күтәрү өчен); көянтә (үлчәүләрдә); 2. *охот. (у собак)* тәпи, аяк; 3. *перен. книж.* этәргеч, кузгаткыч; хәрәкәткә китерүче көч, чара, корал; *социалистическое соревнование — могучий рычаг подъёма производительности труда* — социалистик ярыш хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүнең куәтле этәргече ул.

**РЫЧА'ЖНЫЙ** *тех.* — рычаглы, көянтәле, рычаг белән күтәрә торган; *рычажные весы* — көянтәле үлчәү; *рычажный груз* — рычаг белән күтәрә торган йөк.

**РЫЧА'НИЕ** *ср.* — 1. к. рычать; 2. акырган тавыш, ырлаган тавыш, үкергән тавыш; *послышалось рычание* — үкергән тавыш ишетелде.

**РЫЧА'ТЬ** *несов.* — 1. *(о зверях)* үкерү, (б)акыру, ырлау, ырылдау; 2. *разг. неодобр.* кычкыр(ын)у, җикеренү, бакыру, акыру.

**РЬЯ'НО** *нареч.* — бик тырышып, гайрәтләнеп, ихлас күңел белән бирелеп, дәрт белән, дәртләнеп; *рьяно взяться за что-н.*— берәр эшкә ихлас күңел белән керешү.

**РЬЯ'НОСТЬ** *ж. мн.* нет — гайрәтлелек, тырышлык, бирелеп эшләүчәнлек.

**РЬЯ'НЫЙ: рьяный работник** — тырыш эшче; **рьяный сторонник** — нык (бирелеп) яклаучы; **рьяный охотник** — бик һәвәс аучы; **рьяный игрок** — шәп (хирыс) уенчы; **рьяный человек** — кызу (ярсу) кеше; гайрәтле (дәртле) кеше; **рьяный чтец** — шәп укучы, шәп сөйләүче; **лошади рьяны и молоды были** — атлар яшь һәм ярсу (ярсучарыс) иделәр.

**РЭКЕТИ'Р** *м.* — эре гангстер, шантажчы (АКШта — янаулар-куркытулар белән т[illegible]ләгәненә ирешүче).

**РЮКЗА'К** *м.* — юл капчыгы, арка капчыгы, рюкзак.

**РЮМА'ШКА** *ж. разг. фам.* — к. рюмочка.

**РЮ'МИТЬ** *несов. простореч. неодобр.*— елау, шыңшу, сытылу, яшь агызу, балавыгу.

**РЮ'МКА** *ж.* — рюмка.

**РЮ'МОЧКА** *ж.* — кечкенә рюмка. ◇ Лю

бить рюмочку *разг. шутл.*— хәмер эчәргә (салырга) ярату. **Талия рюмочкой (в рюмочку)** *разг. шутл.* — нечкә билле.

**РЮ'ХА** *ж. обл.* — к. городки.

**РЮШ** *м.* — рюш (бөрелгән юка материя; якага, җиңгә куела).

**РЮ'ШКА** *ж. обл.* — к. рюха.

**РЮ'ШНЫЙ** *обл.*: **рюшная палка** — бура таягы (бурә уенында суккыч таяк).

**РЯБЕ'ТЬ** *несов.* — (әз генә дулкынланудан) шадралану, тигезсезләнү (су, елга өсте).

**РЯБИ'НА** I *ж. бот.* — 1. *(дерево)* миләш агачы; 2. *(плод)* миләш; *кисти рябины* — миләш тәлгәшләре. ◇**Дикая рябина** *бот.* — гөлбадран (үлән).

**РЯБИ'НА** II *ж. разг.* — 1. шадра (эзе); *лицо с рябинами от оспы* — шадра бит; 2. *(пятнышко)* кара тап.

**РЯБИ'НКА** I *ж. разг.* — миләш агачы; (бер) миләш бөртеге.

**РЯБИ'НКА** II *ж. разг.* — кечкенә генә шадра; *рябинка на носу* — борынында кечкенә генә бер шадра(сы бар).

**РЯБИ'ННИК** I *м. обл.* — миләшлек, миләш куаклыгы, миләш агачлыгы.

**РЯБИ'ННИК** II *м. зоол.* — миләш чыпчыгы.

**РЯБИ'ННЫЙ** — миләш ...-ы; *рябинная ягода* — миләш җимеше.

**РЯБИ'НОВКА** *ж.* — рябиновка, миләш аракысы, миләш төнәтмәсе.

**РЯБИ'НОВЫЙ** — 1. миләш ...-ы; *рябиновая настойка* — миләш төнәтмәсе; 2. миләш төсле, сары кызыл. ◇ **Рябиновая** *в знач. сущ. ж.* — к. рябиновка.

**РЯБИ'ТЬ** *несов.* — шадралау, шадралан(д)ыру; чуарлау, тигезсезләү. ◇ **Рябит в глазах** — күз аллары чуарлана.

**РЯБО'Й** — 1. шадра, шадра битле; чутыры; *рябое лицо* — шадра йөз; 2. *просторечь.* чуар, ала, ала-кола; тимгел-тимгел; *рябая курица* — чуар тавык; *рябая корова* — ала сыер.

**РЯ'БЧИК** I *м. зоол.* — боҗыр (кош).

**РЯ'БЧИК** II *м. бот.* — күкбаш, чуарчәчәк (лаләләр төреннән чуар чәчәкле үсемлек).

**РЯ'БЧИКОВЫЙ** — боҗыр ...-ы; *рябчиковые перья* — боҗыр каурыйлары.

**РЯБЬ** *ж. мн.* нет — 1. (су өстендәге) шадрак, вак дулкын; кытыршылык, тигезсезлек; *озеро подёрнулось рябью (Даль)* — күл өсте шадраланып китте; 2. күз аллары чуарлану.

**РЯ'ВКАТЬ** *несов. просторечь.* — бакыру, кычкыру, бугаз киерү, бугаз ярып кычкыру, керәнү; өрү, ырлау, ырылдау.

**РЯ'ВКНУТЬ** *сов. просторечь.* — ырылдап ... өреп алу; акырып җибәрү, акырып ...о.

**РЯД** *м.* — 1. рәт, кат; *в третьем ряду партера* — партерның өченче рәтендә; 2. саф, рәт, ара; *выстроиться в ряд* — сафка басу (шеренгага тезелү); *в рядах армии* — армия сафларында; *в наших рядах* — безнең сафларда, безнең арада; 3. *торг.* базар, лабаз, кибет; *мясной ряд* — ит рәте, ит базары (лабазы); *торговые ряды (устар.)* — сәүдә рәтләре (кибетләр тезелеп киткән урам); *красные ряды (устар.)* — к. красный; 4. *(нижние ряды брёвен в срубе)* нигез, эргә; 5. *только ед. (пробор волос)* чәч юлы, чәч аермасы; *прямой ряд* — туры ачкан аерма; *косой ряд* — яннан ачкан аерма, кыек ачкан чәч юлы; 6. *науч.* рәт, тезмә; *ряд нечётных чисел* — так саннар рәте; *гармонический ряд тонов* — тоннарның гармоник тезмәсе. ◇ **В первых рядах** — иң алда, беренче сафта, иң алдынгы сафларда. **В ряду** *кого-чего устар.*— беррәттән, арасында; рәтендә, исәбендә. **В ряде** *кого-чего* — кайбер, кайсыбер, шактый, күп кенә. **Из ряда вон (выходящий)** — сирәк очрый торган, гадәттән тыш; башкалардан бик нык аерылып тора торган. **Верхний ряд зубов** — өске тешләр. **Ряд поколений** — (бер-бер артлы килгән) берничә буын. **(Целый) ряд** — шактый күп, күп кенә, берничә; *ряд видных учёных* — берничә күренекле галим... **Стать рядами** — рәт-рәт булып басу. **Идти рядами** — саф-саф булып (тезелешеп) бару. **С ряду или по ряду** *просторечь. устар.* — сөйләшкән (сүз куешкан, килешкән, вәгъдәләшкән, шарт) буенча.

**РЯ'ДА** *ж. истор.* — (бәясен) килешү, вәгъдәләшү.

**РЯДИ'ТЬ** I *несов. разг.* — (берәр нәрсәгә) охшатып киендерү, маскарад киеменә киендерү; *рядить стариком*— картка охшатып киендерү. ◇ **В шуты рядить** — 1) сәвәләй итеп киендерү; 2) *перен.* үзен шамакай итеп күрсәтү.

**РЯДИ'ТЬ** II *несов.* — 1. *устар. (наводить порядок, управлять)* тәртип урнаштыру, тәртипкә салу, идарә итү; 2. *просторечь. (нанимать)* яллау.

**РЯДИ'ТЬСЯ** I *несов.* —1. *(наряжаться)* киенү, яхшы (купшы) киенү, киенү-ясану, көязләнеп киенү; 2. маскарад киеменә киенү, берәр нәрсәгә охшатып киенү, сәвәләй (шамакай) булып киенү.

**РЯДИ'ТЬСЯ** II *несов.* — 1. *просторечь. (торговаться с кем-н.)* сатулашу, бәясен (хакын) сөйләшү, бәясен (хакын) килешү; 2. яллану, ...-рга килешү; *рядимся дрова колоть* — утын ярырга ялланабыз.

**РЯДКО'М** *нареч. разг. фам.* — к. рядом 1.

**РЯДНО'** *ср. обл.* — калын киндер.

**РЯ'ДНАЯ** *в знач. сущ. ж. истор.* — к. рядная грамота.

**РЯ'ДНЫЙ** *старин.*: **рядная грамота** — килешү ярлыгы (килешү яки сату шартлары язылган язу); **рядная запись** — бирнә килешүе (әйберләрнең исемлеге язылган язма).

**РЯДОВИ'К** *м.* — рядовой эшче, гади работник (җитәкче түгел).

**РЯДОВО'Й** I — 1. рядовой, гади (җитәкче булмаган); *я рядовой служащий* — мин гади бер хезмәткәр; 2. *(обычный)* һәрвакыттагы, гадәттәге, гадәти, гади; еш очрый (кабатлана) торган; *рядовой случай* — гадәттәге хәл, гадәти хәл. ◇ **Рядовой состав** *воен.* — рядовойлар, рядовойлар составы

(армиядә: солдат, ефрейтор; флотта: матрос, (өлкән матрос). Рядовое звание — рядовой званиесе.

**РЯДОВО'Й** II *с.-х.*: **рядовой посев** — тезмә чәчү; **рядовая сеялка** — тезмә чәчкеч.

**РЯДО'К** *м.* — 1. *разг.* к. ряд 1; *берёзовый рядок* — каеннар тезмәсе (тезелеп киткән каеннар); 2. *истор.* күп кибетле авыл.

**РЯ'ДОМ** *нареч.* — 1. *(один подле другого)* янәшә, бергә, рәттән, янында, беррәттән; *стоять рядом* — янәшә тору, рәттән тору; 2. күршедә генә, янәшә генә, яп-якын, якында гына; *они живут тут рядом* — алар монда гына (якын гына) торалар. ◇ **Сплошь и (или да) рядом** *разг.* — еш кына, күп кенә очракта, күбесенчә, һәрвакыт диярлек.

**РЯДСКО'Й** *устар.*: **рядские учтивости** — сәүдәгәрләр (сатучылар) кебек кылану, илтифат күрсәткән булып кылану.

**РЯ'ДЧИК** *м. устар.* — эшчеләр яллаучы, подрядчы.

**РЯ'ДЫШКОМ** *нареч. разг. фам.* — янәшә генә, янәшә үк, янында ук.

**РЯЖ** *м. спец.* — ряж (күпер, буа, яр буйларын ныгыту өчен эченә таш тутырылган агач бура).

**РЯ'ЖЕН(Н)ЫЙ** I *простореч., обл.* — ялланган, килешкән, килешенгән. ◇ **Суженый-ряженый** — сүз (вәгъдә) куешкан егет, вәгъдәләшкән егет.

**РЯ'ЖЕНЫЙ** II — маскарад киеме ки(дерел)гән, сәвәләй (шамакай) булып киенгән.

**РЯ'ЖЕНЫЙ** III *в знач. сущ. м.*, **РЯ'ЖЕНАЯ** *ж. разг.* — сәвәләй, шамакай, маскалы (маскарад киеме кигән кеше).

**РЯ'ЖЕНЬЕ** *ср. мн.* нет — к. рядить I и рядиться I.

**РЯ'ПУШКА** *ж. зоол.* — ряпушка, чуар балык (Балтик һәм Төньяк дингезләр бассейнында яши торган вак балык төре).

**РЯ'СА** *ж.* — ряса (христиан руханиларының кара материалдан тегелгән, җиләнсыман өске киеме).

**РЯ'СИНА** *ж. обл.* — колга, күсәк.

**РЯ'СКА** *ж. бот.* — бака тәңкәсе (акмас суларда, күлләрдә, буаларда үсә торган вак җепселле яшел суүсем).

**РЯ'СКОВЫЕ** *ср. бот.* — бака ефәгесыман үсемлекләр.

**РЯСОФО'РНЫЙ** *церк.* — ряса һәм клобук кияргә хакы булган (монах).

**РЯХНУ'ТЬСЯ** — к. рехнуться.

**РЯ'ШКА** *ж.* — 1. *обл.* кечкенә чиләк, шайка; 2. *просторeч. презрит. вульг.* ямьсез бит.

## ТӨЗӘТМӘЛӘР

| бит | юл | басылган | укырга |
|---|---|---|---|
| 2 | 30 | *вражской* | *вражеской* |
| 9 | 62 | **ПА'НЦЫРНЫЙ** — панцырьлы; *панцырные рыбы* — панцырьлы балыклар (каты кабыклылар). **ПА'НЦЫРЬ** м.— 1. панцырь | **ПАНЦИРНЫЙ** — панцирьлы; *панцирные рыбы* — панцирьлы балыклар (каты кабыклылар). **ПА'НЦИРЬ** *м.* —1. панцирь |
| 18 | 29 | пассивлаштыру | пассивирлау |
| 134 | 19 | *подобные* | *подобное* |
| 155 | 5 | **ПОЗИЦИ'ОННЫЙ** | **ПОЗИЦИО'ННЫЙ** |
| 166 | 60 | **ПЛОИ'ВКА** | **ПОЛИ'ВКА** |
| 181 | 10 | **ПОМО'РЫ** *м.* | **ПОМО'РЫ** *мн.* |
| 181 | 16 | **ПОМОРЯ'НЕ** *м.* | **ПОМОРЯ'НЕ** *мн.* |
| 204 | 45 | **ПОСТИЖИ'МЫЙ** *ср. книж.* — | **ПОСТИЖИ'МЫЙ** *книж.* |
| 239 | 25 | **ПРИБАВЛЕ'НИЕ** *ср. только ед.* — 1. | **ПРИБАВЛЕ'НИЕ** *ср.*—1. *только ед.* |
| 298 | 32 | тыкшынучан, кеше | тыкшынучан кеше |
| 420 | 20 | **РАСТРАНЖИ'РОВАТЬ** | **РАСТРАНЖИ'РИВАТЬ** |
| 433 | 45—46 | әйләнү хәрәкәт | әйләнмә хәрәкәт |
| 435 | 13 | *выходящие* | *входящие* |

Редакторлары: *Ф. А. Ганиев, Ф. Х. Хәсәнов*
Техник редакторлары: *И. Х. Зәйнуллин, М. Ж. Шәрәфетдинова*
Корректорлары: *Э. Г. Идрисова, З. И. Шагдалеева*

Наборга бирелде 31|X-1957 ел. Басарга кул куелды 7|V-1958 ел. ПФ 03165. Кәгазь форматы $70 \times 108^{1}/_{16}$.
Учет-изд. таб. 64,46. Басма табак 31,0 (42,47). Табакта 68.100 хәреф. Заказ № 0429.
Тираж 20.000. Бәясе 13 сум 10 тиен.

ТАССР Культура Министрлыгының Татполиграф типографиясе,
Казан, Миславский ур., йорт № 9.

безь
рат,
итче
0429.